ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
М.ХӘСӘНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ
ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ
ЭНЦИКЛОПЕДИСТИКА ҮЗӘГЕ

КАЮМ НАСЫЙРИ:

ИЛЛЮСТРАЦИЯЛЕ ПЕРСОНАЛЬ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ

КАЗАН – 2025

УДК 37(470.41)(092)Насыри
ББК 74.03(2Рос.Тат)-8Насыри я20
Н26

Басма Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
М.Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты
тарафыннан әзерләнде

Басманың фәнни мөхәрририяте:
Э.М.Галимова (рәис), Р.В.Шәйдуллин (җаваплы мөхәррир),
Л.М.Айнетдинова, М.Ш.Сибгатуллина, Б.Л.Хәмидуллин

Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия / төз.-авт.: Р.В.Шәйдуллин (төркемнең җитәкчесе), Р.Ф.Исламов, Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Камальтдинова, И.Х.Хәлиуллин, Ф.Р.Бәдретдинова, Г.И.Каюмова. — Казан: М.Хәсәнов исем. Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2025. — 500 б., ил.

Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган персональ энциклопедиядә бөек татар мәгърифәтчесенең фәнни хезмәтләре, педагогик эшчәнлеге, әдәби иҗаты, шулай ук татар халкының аның тарафыннан фәнни нигездә өйрәнелә башлаган этнографиясе һәм фольклоры турында мәгълүматлар тупланган. К.Насыйри татар әдәби теленә нигез салган, аның грамматикасын һәм лексикографиясен системалаштырган, мәктәпләр өчен дәреслекләр язган, үзенең календарьлары, фәнни хезмәтләре һәм әдәби иҗаты белән татар халкының аң-белемен үстерүгә, милли мәдәниятен саклауга бинаһая өлеш керткән мәгърифәтче галим буларак күрсәтелә. Шулай ук аның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты фәнни өйрәнелгән хезмәтләр яктыртыла.

Бу хезмәтне төзүнең төп максаты — К.Насыйриның күпкырлы иҗатын энциклопедик кысаларда туплап, киң даирә укучыга, аеруча милләтебезнең яңа буыннарына җиткерү һәм аның фәнни-мәдәни мирасын саклауга ярдәм итү.

УДК 37(470.41)(092)Насыри
ББК 74.03(2Рос.Тат)-8Насыри я20

ISBN 978-5-902375-88-3

© Аерымланган структур берәмлек
«ТР Фәннәр академиясенең М.Хәсәнов
исемендәге Татар энциклопедиясе
һәм төбәкне өйрәнү институты», 2025

КЕРЕШ

2025 елда татар халкы күренекле мәгърифәтче, язучы һәм энциклопедист галим Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан әлеге зур вакыйганы билгеләп үтә.

Мәгълүм булганча, бөек мәгърифәтче үзенең күпкырлы хезмәте белән татар халкын, аның телен, мәдәниятен, фәнни казанышларын дөньякүләм танытуга зур өлеш кертә. Ул — халыкның бай рухи мирасын җыеп, аны төрле яклап өйрәнеп, эшкәртеп, китаплары һәм календарьлары аша башкаларны да таныштырган, татар халкының данын күтәрүгә барлык көчен куйган олпат шәхес. Мәгърифәтченең үз милләтенә олы мәхәббәт хисе белән сугарылган фәнни, иҗади, наширлек һәм педагогик эшчәнлеге халыкның аң-белемен баетуга, аны милли-мәдәни агартуга юнәлдерелә.

Мәртәбәле вакыйга уңаеннан татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә Каюм Насыйригa багышланган беренче персональ энциклопедия нәшер ителү Татарстан халыклары тормышында истә калырлык зур вакыйга булыр дип ышанам. Энциклопедияне кулына алган һәркем аның сәхифәләре аша мәгърифәтче шәхесенең зурлыгына, аның гыйльми-нәзари кызыксынуларының киңлегенә тирәнрәк төшенер, үзе өчен яңа ачышлар ясар, галимнең тәрҗемәи хәле белән танышканда, ул яшәгән һәм иҗат иткән дәвер, халыкның тормыш-көнкүреше турында күзаллау булдырыр, мәгърифәтченең эшчәнлек һәм аралашу даирәсе аша төрле милләт зыялылары турында күп мәгълүмат алыр. Аның фәнни һәм иҗади сәләте, милли-мәдәни карашлары, халкының рухи көч-куәтенә ышаныч хисләре беркемне дә битараф калдырмас дип уйлыйм.

Әлеге саллы хезмәт Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең М.Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан әзерләнде. Аны татар милли мәдәниятенең үткәнен — бүгенге белән, бүгенгене — киләчәк белән тоташтыручы күпер дип әйтергә мөмкин. Хәзинәгә тиң бу энциклопедик басма безне алга таба да изге, игелекле эшләргә генә рухландырып торыр, яңадан-яңа казанышларга көч бирер, халкыбыз мирасын киләчәк буыннарга түкми-чәчми тапшырырга ярдәм итәр.

Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны билгеләп үтү турында махсус фәрман имзалаган Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнехановка, «Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия»сен гамәлгә куюга зур ярдәм күрсәткән ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе М.Г.Әхмәтовка, шулай ук төрле фән тармаклары галимнәренә, музей һәм китапханә хезмәткәрләренә, төбәк җитәкчеләренә, мөгаллимнәргә һәм әлеге басмага хезмәте кергән һәркемгә мөхәрририят исеменнән тирәнтен зур рәхмәтемне белдерәм.

Э.М.Галимова,
Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры,
сәнгать фәннәре кандидаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе,
РФнең һәм ТРның Композиторлар берлеге әгъзасы, РФнең һәм ТРның Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы, М.Җәлил исемендәге Республика бүләге лауреаты

УКУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА

Бер томлы Каюм Насыйри энциклопедиясе — татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә К.Насыйриның тәрҗемәи хәленә һәм күпкырлы эшчәнлегенә багышланган беренче персональ энциклопедия. Әлеге энциклопедиянең төзелүе һәм нәшер ителүе К.Насыйриның тууына 200 ел тулуның татар халкының фәнни-мәдәни тормышында зур вакыйга буларак билгеләп үтелүе белән бәйле.

К.Насыйриның гасыр ярымнан артык вакыт эчендә төрле җыентыкларда, аерым китап-календарьларында тупланган, беркадәре әле хәзер дә кулъязма хәлендә сакланучы фәнни хезмәтләре һәм әдәби мирасына, ачышуңышларына, аларның әһәмиятенә гомуми йомгак-нәтиҗә ясау, галимнең тәрҗемәи хәлен, фәнни һәм иҗади юлын, яшәгән мохит-даирәсен, тормышына һәм эшчәнлегенә зур йогынты ясаган шәхесләрне мөмкин булган кадәр төгәллек белән ачыклау, фәнни-гамәли иҗатының төрле өлкәләрендә аның энциклопедист галим һәм татар мәгърифәтчесе буларак чагылышын системага салып барлау вакыты да җиткән иде.

2023 елның 22 мартында Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнехановның «Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуны бәйрәм итү турында»гы Указы киң җәмәгатьчелеккә җиткерелү белән, ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты Каюм Насыйри энциклопедиясен төзү турында тәкъдим белән чыкты. Әлеге гаять әһәмиятле мөмкинчелектән файдаланып, институтның Энциклопедистика үзәгеннән бер төркем галимнәр һәм фәнни хезмәткәрләр бу эшкә алынырга батырчылык итте. Проектның җитәкчесе тарих фәннәре докторы, профессор Рафаил Шәйдуллин, моңа кадәр дөнья күргән берничә Россия һәм Белоруссия персональ энциклопедияләре, шул исәптән Габдулла Тукай һәм Салават Юлаев энциклопедияләре белән танышып чыгып, алардагы безнең энциклопедияләргә дә хас һәм күп кенә үзенчәлекле якларны үрнәк итеп алып, басманың гомуми концепциясен, структурасын эшләде. Персональ энциклопедия өчен җаваплы төркем (Р.Ф.Исламов, Ф.Р.Бәдретдинова, Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Камальтдинова, Г.И.Каюмова, И.Х.Хәлиуллин) энциклопедиядә урын алырга тиеш дип уйланылган мәкалә һәм белешмәләрнең исемлеген төзеп эшкә кереште.

Персональ энциклопедия тугыз тематик юнәлешкә караган, һәрберсе татар дөньясында уникаль К.Насыйри феноменын, аның күпкырлы фәнни-гамәли эшчәнлеген ачуга хезмәт итә алырлык дип фаразланган мәкалә һәм белешмәләрне үз эченә ала.

Беренче тематик юнәлеш мәгърифәтченең үзе исән вакытта дөнья күргән һәр китабына һәм рус телендә язылган берничә мәкаләсенә фәнни-нәзари күзлектән шәрехләнгән, темасы, проблематикасы, эчтәлеге, басмалары (шул исәптән сайланма әсәрләре) һәм башка хосусиятләре тикшерелгән энциклопедик белешмәләрдән тора.

Икенче тематик юнәлештә К.Насыйриның еллык календарьлары проблематик планда карала. Һәр календарьда аның тарафыннан бастырылган мәкаләләрнең, бер-берсе белән кабатланмыйча, кыскача эчтәлеге күрсәтелә.

Өченче тематик юнәлештә, иҗтимагый-сәяси һәм милли-дини мәсьәләләр белән бәйләнештә, К.Насыйриның руханилар уку йортларында, рус-татар мәктәбендә укытуы гомуми һәм проблематик планда карала, ягъни аның фикерләү үзенчәлекләре, педагогик алымнары, шулай ук дини-әхлакый карашлары игътибар үзәгенә куела, халыкчанлык, миллилек һәм башка мәсьәләләр тикшерелә.

Дүртенче тематик юнәлештә сүз мәгърифәтченең нәсел-тамыры, туганнары, танышлары, замандашлары (галимнәр, әдипләр, аның хакында хатирәләр язучылар һ.б.), укучылары турында бара. Әлеге юнәлештәге мәкаләләр һәм белешмәләр өчен төп чыганаклар булып К.Насыйриның үз нәселе турындагы язмалары, мәгърифәтче хакында авылдашлары һәм аның белән турыдан-туры яки хезмәтләре аша таныш булган замандашлары язып калдырган истәлекләр, китапханә, архив, музей фондларында саклана торган документлар һәм иллюстратив материаллар хезмәт итә.

Бишенче тематик юнәлештә сүз К.Насыйриның татар тел белеме, әдәбияты, фольклоры, тарихы, этнографиясе һәм гомумтабигыять гыйлеме өлкәләрендәге эшчәнлеген аерым мәкаләләрдә күрсәтү, үзенчәлекле фикер-карашларын яктырту мәсьәләләре хакында бара.

Алтынчы тематик юнәлешкә К.Насыйриның тәрҗемәи хәлен һәм күпкырлы фәнни-гамәли иҗатын өйрәнүгә һәм барлауга үз өлешен керткән татар, рус һәм башка милләт галимнәренең эшчәнлеге яктыртылган белешмәләр керә. Алар Шәрекъ һәм Европа әдәбияты, шулай ук татар халык авыз иҗаты үрнәкләренең бәрәкәтле тәэсирен тойган К.Насыйриның язма һәм гамәли мирасын өйрәнүгә багышланган материаллардан гыйбарәт. Мәгърифәтченең дүрт томлы сайланма әсәрләре басылып чыкса да, әле дә байтак хезмәтләре (шул исәптән календарьларындагы мәкаләләр) гамәлдәге татар язуына күчерелмәгән. Шул сәбәпле, аның иҗатын энциклопедия кысаларында бар тулылыгында чагылдыру мөмкинлеге булмады. Биредә шулай ук мәгърифәтченең тормышы һәм иҗаты белән бәйле Гыйльми үзәк чаралары, аның юбилей даталарына бәйләп нәшер ителгән җыентык материаллары, төрле фәнни-гамәли форумнар чагылыш таба.

Җиденче тематик юнәлештәге мәкаләләрдә К.Насыйри шәхесе һәм иҗатының татар мәдәниятенең төрле юнәлешләрендә — сынлы сәнгатьтә (портретлар һәм бюстлар), театр һәм әдәбиятта (драматургия, проза, шигърият) яктыртылышы тикшерелә.

Сигезенче тематик юнәлештәге мәкалә һәм белешмәләрдә К.Насыйри тормышы белән бәйле урыннар: Казан губернасының аның иҗатында чагылыш тапкан Зөя өязе авыллары (шул исәптән, Югары Шырдан (хәзер Кече Шырдан), Олы Ачасыр, Бәчек, Күгеш һ.б.), Казан шәһәре, Сәгыйд бистәсе, Мәкәрҗә ярминкәсе һ.б., ул яшәгән йортлар, укыган мәдрәсәләр, эш урыннары; шулай ук Казандагы, Яшел Үзән районындагы аңа багышланган музейлар, аның исемен йөрткән институт, мәктәп, урам һ.б. турында мәгълүмат бирелә.

Тугызынчы тематик юнәлештәге мәкаләләрдә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреатларының (аерым шәхесләр һәм коллективлар) эшчәнлеге яктыртыла.

Кушымтада ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреатлары исемлеге, шулай ук К.Насыйриның Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязма һәм сирәк китаплар бүлеге һәм ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондларында сакланган хезмәтләре, кулъязмалары һәм аңа кагылышлы материаллар исемлеге (таблицаларда) китерелә.

Әлеге энциклопедистик басманың структур һәм композицион төзелешенә килгәндә, ул К.Насыйриның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә гомуми күзәтү ясалган күләмле мәкаләдән башлана. Әлеге текст мәгълүмат эзләүне җиңеләйтү максатыннан төп тексттан аермалы шрифтта җыелган һәм сылтамалар белән тәэмин ителгән. Энциклопедиянең төп өлешендә мәкаләләр һәм белешмәләр алфавит тәртибендә урнаштырылган. Энциклопедистиканың «түгәрәк буенча уку» принцибыннан чыгып, мәкаләләрнең шактый өлеше сылтамалар һәм өлешчә сылтама-мәкаләләр белән ныгытылган. Шулай ук кайбер очракларда (мәсәлән, аерым мәкаләләрне кушымталар белән бәйләү өчен) гиперсылтамалар да бирелгән.

Мәкалә ахырында чыганаклар, әсәрләр һәм әдәбият исемлеге урнаштырылган. «*Әсәр.*:» дигәндә, К.Насыйриның үз әсәрләре һәм башка авторларның басмалары күрсәтелә; «*Хезм.*:» дигәндә, мәкалә авторының үз хезмәтләре китерелә. Әсәрләр һәм хезмәтләр хронологик тәртиптә урнаштырыла, аларда авторның исем-фамилиясе күрсәтелми. «*Чыг.*:» төшенчәсе теге яки бу мәкаләне язганда файдаланылган хезмәтләрне күздә тота һәм чыганак авторының исеме күрсәтелә. «*Әд.*:» өлешендә теге яки бу мәкаләне язганда кулланылган хезмәтләр исемлеге татарча басмалардан башлап (аннары рус һәм чит телләрдә) бирелә, авторның исеме куела.

Кайбер аббревиатураларны (СССР, КПСС һ.б.) исәпкә алмаганда, Каюм Насыйри энциклопедиясендә шартлы кыскартылмалар юк диярлек.

Әлеге энциклопедиядә, өстәмә һәм күрсәтмә мәгълүмат чыганагы буларак, төрле иллюстратив материал урнаштырыла. Иллюстрацияләрне басмага әзерләүчеләр: Г.Р.Дәүләтьянова, Р.Н.Шакиров; дизайнер: Ф.Ә.Ибраһимова, китапны компьютерда биткә салучылар: Р.Р.Сәләхиев,

А.Б.Насибуллина. Энциклопедияне төзү һәм редакцияләү эше башлыча ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты хезмәткәрләре тарафыннан башкарылды.

Әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелекне, гомумән, киң катлау укучыларны Каюм Насыйри энциклопедиясе төзүнең эш барышы белән таныштырып тору максатында Р.В.Шәйдуллин, Р.Ф.Исламов, Ф.Р.Бәдретдинова, Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Камальтдинова, Г.И.Каюмова, А.Б.Насибуллина, Р.Р.Сәләхиев, И.Х.Хәлиуллин һәм башка авторлар вакытлы матбугатта чыгыш ясыйлар, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашалар, язмаларын фәнни, фәнни-популяр җыентыкларда бастыралар. Персональ энциклопедиянең фәнни-методик нигезләре һәм контент мәсьәләләре Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында 2024 елның апрелендә махсус уздырылган «Каюм Насыйри персональ энциклопедиясенең текст һәм иллюстрацияләр контентлары икърар ителешенең фәнни-методик үзенчәлекләре» түгәрәк өстәлендә һәм башка форумнарда каралды.

Китапның ахырында институт директоры Э.М.Галимова мөхәрририят исеменнән әлеге күләмле һәм җитди хезмәтне гамәлгә куюга ярдәм күрсәткән дәүләт эшлеклеләренә, галимнәргә, музей һәм китапханә хезмәткәрләренә, төбәк җитәкчеләренә, педагогларга һәм башкаларга олы рәхмәтен белдерде (тулырак кара кушымтаны: *Рәхмәт сүзе*).

Мөхәррирдән



КАЮМ НАСЫЙРИ
(1825–1902)

КАЮМ НАСЫЙРИ (Насыйри Габделкаюм Габденнасыйр улы), мәгърифәтче, фольклорчы, этнограф, нашир; хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы, җыеп әйткәндә, энциклопедист галим. 1825 елның 14 (искечә — 2) февралендә Казан губернасының Зөя өязе (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы) Югары Шырдан (хәзер *Кече Шырдан*) авылында рухани гаиләсендә дөньяга килә.

К.Насыйри — күпкырлы фәнни һәм наширлек, мәдәни-агарту эшчәнлеге белән исемен татар халкына гына түгел, бөтен дөньяга таныткан шәхес. Татар һәм рус зыялылары аны юкка гына «татар Ломоносовы», «татар Леонардо да Винчие» дип зурламагандыр. Ул — гомере буе халкына фидакарьләрчә хезмәт иткән, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласына әверелдергән татар галимнәренең берсе. К.Насыйри соңгы көннәренә кадәр мәгърифәт юлындагы эшчәнлеген ташламый. «Үзегез карт, күзләрегез зәгыйфь булса да, язуыгызны дәвам итәсез икән» диючеләргә ул: «Алла мине язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», — дип җавап бирә торган була.

Нәселе. Каюм Насыйри борынгы ыруга карый, аның нәсел башы Казан ханлыгы чорында ук Иделнең уңъяк ярында Болгарстан ягыннан килеп төпләнгән Бираш исемле кешегә барып тоташа. «Җиденче буынга кадәр» бабалары барысы да укымышлы кешеләр булган. К.Насыйриның бабасы Хөсәен Мукаев (1760–?) атасы Әлмөхәммәттән яхшы дини тәрбия һәм белем ала. Әлмөхәммәт улы Хөсәен күп еллар Югары Шырдан авылында имам булып тора. Коръәнне ким дигәндә 100 тапкыр күчереп яза, нәхүне (синтаксис) яхшы белә. К.Насыйриның кайбер мәгълүматларына караганда, бабасы «Шәрхе мелла» (грамматика буенча), «Мисбах» (дин нигезләре буенча), «Сарыф һәваи» (синтаксис буенча) исемле китаплар яза. Аның өч улы була: Габденнасыйр, Мөхәммәтгалим һәм Хөснетдин. Каюмның атасы Габденнасыйр *Хөсәенов* берничә телне, шул исәптән гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белә. Авылдашларының киңәшчесе сыйфатындагы ышанычлы кеше була. Коръән гыйлемен сәламәт практицизм белән берләштереп, ике дөньяны — илаһият һәм җир тормышын тигез күреп яши. Хәлле гаилә башлыгы була. Г.Хөсәенов улларын да сәләтләренә карап укыта, шул рәвешчә аларны олы тормышка әзерли (тулырак кара: *Насыйрилар нәселе*).

Габденнасыйрның башка угылларыннан аермалы буларак, К.Насыйри, нигездә, фәнни-агарту эшчәнлеге белән шөгыльләнсә дә, аңарда эшмәкәрлек сәләте дә күзәтелә. Китапларын бастыру һәм сату өчен үз басмаханәсен һәм китап сату фирмасын булдырырга тырышып карый. Егерме елдан артык вакыт дәвамында бастырып чыгарган календарьлары гына да — шуның ачык мисалы. Мәгърифәтче аларны төзеп кенә калмый, үзе рәсемнәр һәм карталар да ясый, үз акчасына бастыра, тарату һәм сату белән шөгыльләнә, кергән керемгә яңа календарьлар һәм хезмәтләр нәшер итә. Татар галимнәре арасында беренчеләрдән булып, китапларны сату өчен билгеле бер уңайлылык тудырган реклама рәвешендәге *«Игъланат»* басмасын чыгара. Галим, нигездә, китап сату, укыту һәм өстәмә эшчәнлекләреннән кергән акчага яши. Васыятеннән күренгәнчә, мохтаҗлыкта гомер кичерми (кара: *«Васыятьнамә»*).

Уку-укыту еллары. Буыннан-буынга килгән гыйлем-мәгърифәткә омтылыш К.Насыйриның киләчәген алдан ук билгеләп куя сыман. Башлангыч белемне әтисе мәктәбендә алганнан соң, 1841 елда Казанга *«Касыймия»* мәдрәсәсенә укырга китә. Ул чорда мәдрәсәләрдә белем бирү сыйфаты *Татарстан Республикасы Дәүләт архивында* сакланган документларда ачык күренә. Мәсәлән, Казан шәһәренең Россия Халык мәгарифе министрлыгына буйсынмаган мөселман мәктәпләре турында 1854 елгы ведомостьта мәдрәсәдә өйрәнелгән фәннәрнең исемлеге бирелгән. Әлеге мәгълүматларга күз салсак, бу дәвердә гарәп, фарсы, төрек һәм башка телләрдә уку һәм язу; күпмедер дәрәҗәдә Коръәннән дә белемнәр бирү һәм арифметика кагыйдәләрен татар телендә өйрәтү каралган булуы аңлашыла. Шәрекъ телләрен белү мөселман Якын Көнчыгышы илләре фәне һәм мәдәнияте белән танышу өчен зур мөмкинлекләр ача. Шул чор шәкерте буларак,

К.Насыйри да телләр өйрәнүгә һәвәс була, мәдрәсәдә укыганда ул гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә, рус телен мөстәкыйль рәвештә үзләштерә, шушы телләрдәге әдәбиятлар белән якыннан таныша. 1855 елда «Касыймия»не пишкадәм таныклыгы белән, ягъни «бишле» билгеләренә генә тәмамлый. Мондый таныклык аңа мулла яки, мәдрәсәдә кече мөгаллим булып, шәкертләр укыту хокукы бирә.

1855 елда К.Насыйри *Казан өяз руханилар училищесы* ректоры протоиерей Ираклий Лепоринский тәкъдиме белән анда татар теле дәресләре укыта башлый. Укыту елларында аның тормышында шәркыятьче галим, Казан руханилар академиясе профессоры Г.С.*Саблуков* зур роль уйный. Аның тәкъдиме белән К.Насыйри *Казан руханилар семинариясенә* укытучы итеп билгеләнә. Ул анда укучыларга татар теле грамматикасын, татар телендә Инҗилне һәм татарча сөйләм телен өйрәтә. Аның ярдәмендә гамәли класс семинаристлары фигыль һәм исемнәрне төрләндерергә, сүзләргә грамматик анализ ясарга өйрәнәләр. К.Насыйриның мөгаллимлек эшенә җитди каравының нәтиҗәсе буларак, семинария укчылары арасыннан да галимнәр чыга: шуларның берсе — П.П.*Масловский*. К.Насыйри руханилар семинариясендә укытучылык эшчәнлеге өчен 1857–1858 елларда айга 8 сум 33 тиен хезмәт хакы ала, аның чардагының бер бүлмәсендә яши. Мөгаллимлек эшчәнлегеннән тыш, К.Насыйри татар теле сүзлекләре һәм *грамматикасы* төзү белән дә шөгыльләнә. Аның Казан руханилар семинариясендә эшләгән елларында рус телен өйрәнүче татарлар һәм татар телен өйрәнүче руслар өчен чыгарылган «Кыскача татар нәхүе» (1860) — тел белеменә караган беренче фәнни казанышы. Мәгърифәтченең әлеге хезмәте белән танышып чыккан әдәбият галиме Габдрахман *Сәгъди 35* яшьлек К.Насыйрины өлгереп җиткән алдынгы филолог һәм татар тел белгече буларак бәяли.

Руханилар уку йортларында озак еллар эшләү дәверендә рус укытучылары белән тыгыз элемтәдә тору, алар белән даими аралашу аның рус мәдәнияте белән кызыксынуын тагын да арттыра. Нәтиҗәдә, Россиядә яшәүче татарлар үз иленең тарихын, мәдәниятен һәм туган теле белән беррәттән рус телен дә белергә тиеш дип санаган К.Насыйри 1871 елда татар, башкорт һәм кыргыз мәктәпләре инспекторы В.В.*Радлов* тәкъдиме белән татар балаларына рус теле нигезләрен өйрәтү өчен Казанда беренче башлагыч мәктәп ача һәм укыту эшчәнлеген *татар-рус мәктәбендә* дәвам итә. Әмма әлеге эшләрне башкару өчен шартлар җиңел булмый, бина табу, балаларны укуга тарту өчен бик күп тырышлык куярга, төрле авырлыклар кичерергә туры килә. Өстәвенә Казандагы татар мәдрәсәләренә рус телендә белем бирүче мөгаллимнәрне җәлеп итү күпчелек татарлар арасында ризасызлык уята. Бу мәсьәләдә аеруча иске карашлы муллалар, дин әһелләре җитди каршылык күрсәтә, алар арасында русчаның файдасына караганда, зыяны күбрәк дип санаучылар бихисап була. Шиһабетдин *Мәрҗани*, Хөсәен Фәезханов, К.Насыйри башка бер милләтнең кул астында яшәгән татар халкына рус телен өйрәнү, һичшиксез, кирәк дип саныйлар, патша хөкүмә-

тенә уку-укыту, мәдәни, дини һәм иҗтимагый-икътисади мәнфәгатьләр мәсьәләсендә мөрәҗәгать итү мөһимлеге килеп туа калса да, шулай ук аралашу өчен дә рус теленең кирәклеген яклап чыгалар. Шук ук вакытта алар татар телен, татар халкының гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү, татарча сүзләр арасына русча сүзләр катыштырып сөйләшүдән саклану тиешлеген катгый итеп куялар.

К.Насыйри, үз дәвере уку-укыту торышының заманча булмавын аңлап, аны үзгәртергә, камилләштерергә омтыла. Россиядәге фәннәрне һәм һөнәрләрне өйрәнү өчен татарларның рус телен белүе шарт дип саный. Шәхси мәктәбендә дә яңа дөньяви фәннәр кертергә, булганнарын үзгәртеп төзергә кирәк дип таба. Үзенең дә русчасы яхшы булган К.Насыйриның рус мөгаллимнәре белән аралашуы, аларны зурлавы кадимче муллаларда нәфрәт уята, алар аның рус-татар мәктәбендә укытуын дини яктан зәгыйфьлеге белән аңлаталар. Дингә аркаланып, гади халыкны кадимчелеккә тарткан, күзләрен томалаган муллалар һәм аларга ышанган татарлар мәгърифәтченең заманча, европача укытуына каршы чыгалар. Шул сәбәпле 1876 елда К.Насыйри әлеге мәктәптәге укыту эшен туктатырга мәҗбүр була. Моңа бәхетсезлек очрагы да килеп кушыла: мәгърифәтче эшләгән иске уку йортының черегән идәне җимерелеп, ул тирән чокырга егылып төшә һәм чак кына суга батып үлми кала. Әлеге фаҗигале вакыйгадан соң, шулай ук карагруһчыларның даими тискәре йогынтысы аркасында тирән нерв киеренкелеге кичергән мәгърифәтче озак дәвалана һәм мәктәпкә кире кайтмаска була.

К.Насыйри еллар дәвамында тупланган педагогик тәҗрибәсен шәхси мәктәбендә һәм татар шәкертләренә уку әсбаплары әзерләүдә киң куллана. Ул алга таба да, өйдә укыту эшчәнлеген дәвам итү максатыннан 1876 елның 3 июлендә Оренбург Мөселман Диния нәзарәтендә уңышлы гына имтиханнар тапшырып, имам-хатип һәм мөдәррис исеменә лаек була. Шул ук елда ачылган *Казан татар укытучылар мәктәбендә* укыту эшен берничә ел дәвам итә. Бу уку йортыннан соң да ул мәгърифәт эшчәнлеген бөтенләй үк ташлап бетерми, кайбер татар эшмәкәрләре һәм зыялыларының балаларына хосусый дәресләр бирә.

К.Насыйри *«Хисаплык»*, *«Гыйльме һәндәсә»*, *«Осуле җәгърәфияи кәбир»* кебек уку әсбапларын төзегәндә, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, татар телендә фәнни терминология дә эшли. Аның *арифметикага* керткән күп кенә сүзләре татар әдәби теленә ныклап кереп киткән һәм математика дәреслекләрендә хәзер дә кулланыла (мәсәлән, сан, жыю, алу, бүлү, калдык һ.б.). Арифметика, геометрия, *география*, *ботаника* һәм башка фәннәр буенча хезмәтләре белән К.Насыйри татар яшьләренә дөньяви белемнәргә киң юл ачып кына калмый, аларга фәнни юнәлештә алга таба эшләү өчен ныклы җирлек тә әзерли. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә урта гасырлардан яшәп килгән ятлаулар урынына ул уку-укыту системасында җанлы атмосфера тудыруны, күрсәтмә ысуллар кертүне тәкъдим итә. Теге яки бу фәнне өйрәткәндә, укучыларның танып белү активлыгын стимул-

лаштыру максатыннан дәресләрдә мавыктыргыч ситуацияләр тудыруга, төрле фәннәр буенча белемнәрне тормыштан алынган мисаллар белән ныгытуга өстенлек бирә, бер системага салынган күнегүләр кертә. Шулай ук ул тел, аны укыту мәсьәләләре хакында да мөһим генә фикерләр әйтә, татар теле дәресләрен халык авыз иҗатыннан һәм тормыштан алынган кызыклы мисаллар белән бәйләп укытуны яклап чыга.

Фәнни-гамәли һәм наширлек эшчәнлеге. К.Насыйри гомере буе белем туплый, өйрәнә, фәнни-гамәли эшчәнлек алып бара. Ул төрле фәннәрдән хәбәрдар була. Аның рәсем ясау, сызым, китап төпләү, табиплык, балта һәм тимер эшләре белән шөгыльләнүе дә мәгълүм. Петербург университеты профессоры, шәркыятьче галим В.В.*Григорьев* 1880 елда ук инде К.Насыйриның гаять белемле кеше булуы хакында язып чыга. «Мин, татарлар арасында мондый кеше булыр дип һич уйламый идем», — ди галим. Мәгърифәтче Казан университеты белән шактый тыгыз элемтәдә тора. Казан руханилар семинариясендә эшләгәндә, университетка ирекле тыңлаучы буларак лекцияләргә йөри. 1885 елда Казан университеты янындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең* гыйльми әгъзасы итеп сайлана.

1879 елда К.Насыйри рәсми уку йортларында даими эшләвен туктата һәм калган гомерен язучылык, тәрҗемәчелек һәм фәнни-тикшеренү эшләренә багышлый. Мәгълүм булганча, аның фәнни эшчәнлеге 1855 елдан башланып китә. Бу елда аны Казан өяз руханилар училищесына татар теле укытучысы итеп чакыралар. Алдында торган төп бурычларның берсе буларак, ул татар телен мөмкин кадәр яхшырак өйрәтү тиешлеген аңлап эш итә. Аңа кадәр дә татар теле төрле уку йортларында укытыла, Казан университетында да предмет буларак аерым өйрәнелә. К.Насыйри университет тәҗрибәләрен дә үзләштерә, татар җанлы сөйләм телен өйрәнүгә зур игътибар бирә. Бу аның шул чордагы тел белеменә караган хезмәтләреннән дә аңлашыла. Шул ук вакытта мәгърифәтче иске татар әдәби телен дә кире какмый. Аның фәнни карашлары формалаша һәм торган саен ныгый. Ул Шәрекъ филологиясе гыйлеме өйрәтмәләренә нигезләнгән фикер йөртүдән берникадәр читләшә, Европа мәгърифәтче галимнәре йогынтысында барлыкка килгән һәм үсеш алган европача метод һәм методологияләргә күчеш этабын нәтиҗәле уза.

Мәгълүм булганча, К.Насыйри — хәзерге татар әдәби теленә нигез салучыларның, татар тел гыйлемен яңа фәнни баскычка күтәрүчеләрнең берсе. Аның югарыда искә алынган «Кыскача татар нәхүе» (1860) дәреслек-кулланмасы — шуның ачык мисалы. Ул — К.Насыйриның тел гыйлемен өйрәтүгә, аның фәнни-гамәли нигезләрен булдыруга никадәр җитди карашта торуын раслаучы хезмәт. Бу уңайдан тел галиме Шиһабетдин *Рамазанов* болай дип яза: «19 йөзнең соңгы яртысына чаклы татар әдәби теленең теоретик нигезләре, сөйләм һәм язу нормалары, стилистик алымнары билгеләнмичә килде. Бу мәсьәләләрне һәм бу идеяләрне беренче буларак Каюм Насыйри күтәреп чыкты. Татар милли әдәби телен нигез-

ләү, аның потенциаль мөмкинлекләрен һәм бик нечкә хасиятләрен ачып бирү, грамматик, орфографик һәм орфоэпик нормаларын кагыйдәләштерү бурычларын тарих Насыйригa йөкләгән». Ул тел белемен өйрәнү эшчәнлегендә үз халкының җанлы сөйләменә, гасырлар дәвамында җыела килгән халык авыз иҗаты ядкәрләренә мөрәҗәгать итә, аларны җыйнап, эшкәртеп, китап итеп чыгара, һәм бу аның язучылык таланты ачылуга да зур этәргеч була.

К.Насыйри татар теленең байлыгы, бөтенлеге һәм камиллеге турында үзе болай яза: «Инде телебезгә игътибар итеп, яхшы тикшереп карасаң, шунысы ачыклана: телебездә булган бәетләр, шигырьләр, мәкальләр, табышмаклар гаять төзек ритмлы һәм рифмалы итеп төзелгәннәр; телебез гарәп һәм фарсы сүзләре катнашында мәгънәне тулы һәм матур бирүдә башка телләрдән һич тә ким түгел. Ләкин шуны да әйтеп китәргә кирәк: телебез, бер дә кузгалмыйча, бер урында утырып калган». Мәгърифәтче татар теленең кагыйдәләрен, үзенчәлекләрен ныклап өйрәнергә, шуның ярдәмендә аны камилләштерергә чакыра. Татар телен кимсетеп караучыларга җавап итеп: «Ялган, яла бу! Без — татарлар, телебез — татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул», — ди. Аның фикеренчә, телнең аерым бер кеше яисә милләт тормышында әһәмияте бик зур. «Хәзерге заманда башка милләт халыкларының максаты — телне камилләштерүдер», — ди ул. Үз телеңне камил белү башка телләрне өйрәнү өчен дә төп алшарт булып тора, К.Насыйри да шул фикерне раслый: «Әгәр башка телне өйрәнәсе булсаң, — дип яза мәгърифәтче, — ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү бик кирәк».

Тел — укыту, тәрбия бирүнең, милли үзаңны үстерүнең төп нигезе. Олуг мәгърифәтче шуны яхшы аңлый һәм төп игътибарын телне үстерү һәм камилләштерүгә юнәлтә. Ул татар халкының заманча *тел белемен* һәм аның грамматикасын эшләүгә зур өлеш кертә. Халыкның сөйләмен камилләштерү өчен, ул тел үзенчәлекләрен белергә тырыша, аны язуда дөрес чагылдыру ысулларын эзли, сүзләрнең яңгырашын мөкаммәл тасвирлаучы язу кагыйдәләрен булдыра, шул рәвешчә тел гыйлеме ярдәмендә дөрес сөйләү кагыйдәләрен гамәлгә кертүгә юл ача. К.Насыйри, китапларын татарча язып, төрек, гарәп, рус, фарсы телләреннән күп кенә ядкәрләрне тәрҗемә итеп, татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтә, тел мөмкинлекләрен тагын да арттыра, баета. Хезмәтләренең шактые татар теленә багышланган: *«Кавагыйде кыйраәте русия»* (1890), *«Иршад әл-әхба»* (1901), *«Кавагыйде китабәт»* (1892), *«Әнмүзәҗ»* (1895), *«Иҗек»* (1895) һ.б. Бер үк вакытта галим тел белеменең аерым бер тармагы саналган татар лексикографиясен дә яңа биеклеккә күтәрә: татар теленең заманы өчен аерым игътибарга лаек ике томлы аңлатмалы сүзлеген (*«Ләһҗәи татари»*, 1895–1896), рус-татар сүзлекләре («Татарча-русча лөгать китабы» — *«Татарско-русский словарь»*, 1878; «Рус хоруфе һәҗас үзә мөрәттиб лөгать китабы» — *«Полный русско-татарский словарь»*, 1892) төзи (тулырак кара: *Лексикография*).

К.Насыйри бер үк вакытта татар халык авыз иҗатын да өйрәнә. Фәннең әлеге юнәлеше белән кызыксынуы аның татар теле нигезләрен өйрәнү буенча гыйльми эзләнүләре белән тыгыз бәйле. Мәгърифәтченең халык иҗатына мәхәббәте руханилар уку йортларында укытканда ук уяна. Димәк, К.Насыйриның фольклористикага тартылуы очраклы күренеш түгел: аның дөньяга карашы формалашуда, теге яки бу мәсьәләгә мөнәсәбәтле гыйльми фикерләре һәм күзаллаулары барлыкка килүдә, иҗатының халыкчанлык рухында үсеш алуында, аннары европачыл мәгърифәтчелек позицияләренә күчешендә татар теле зур роль уйный. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге, фольклорчы галим Хәмит *Ярми* билгеләп үткәнчә, түбәндәгедән гыйбарәт: беренчедән, ул, татар фольклорын турыдан-туры халыкның үз авызыннан язып ала, җыеп туплаган материалларның иң яхшы үрнәкләрен бастырып чыгаруга зур игътибар бирә; икенчедән, башка халыкларны үз халкының тарихы, тормыш-көнкүреше, дөньяга карашы белән таныштыру максатыннан татар халык авыз иҗаты әсәрләренең иң үзенчәлеклеләрен рус телендә бастырып чыгаруга күп көч куя; өченчедән, Көнчыгыш фольклорын җентекле өйрәнеп, аның шактыен татарчага тәрҗемә итеп бастыра.

Халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм системага салып бастыру барышында, К.Насыйри аларны билгеле бер жанрларга аера, жанрларга — билгеләмәләр, аерым әсәрләргә искәрмәләр, аңлатмалар бирә. Аңа кадәрге һәм замандаш галимнәрнең (Г.Вahапов, С.Кукляшев, М.Салихов, Г.Фәезханов, Т.Яхин, Н.Ф.Катанов, В.В.Радлов һ.б.) халык авыз иҗатына багышланган хезмәтләре белән чагыштырганда, аның хезмәтләре, бер яктан, материалның күләме һәм сыйфаты, фольклорның барлык жанрларын да диярлек үз эченә алуы белән аерылып тора. К.Насыйриның Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә татар фольклоры әсәрләрен тапшыруы уңае белән күренекле төрки телләр галиме Н.Ф.*Катанов* болай дип яза: «Бу көнгә кадәр Казан татарларының халык иҗаты ядкәрләрен җыйнаучылардан берәүнең дә бу хәтле күп мәкальләр һәм җырлар тапшырганы юк иде. Насыйров әфәнде тапшырган материаллар, бөтен гомерен үз халкы арасында үткәреп, аны төрле яклап өйрәнүе сәбәпле, аның үз халкының тормышы һәм теле белән яхшы таныш булуын бик ачык күрсәтә».

Икенче яктан, фольклор әсәрләрен җыю һәм бастыру, аларны әдәби әсәрләрдә, тел белеме, тарихи-этнографик хезмәтләрдә файдаланудан тыш, К.Насыйри халык авыз иҗатының аерым фән буларак өйрәнелә башлавына нигез сала. Халык *җырлары*, *бәетләре*, такмаклары мөстәкыйль гыйлем булырга тиеш дип саный һәм һәркайсын аерым өйрәнә. Дөрес, К.Насыйриның үзе җыйган материалларны фольклор җыентыклары итеп чыгару мөмкинлеге булмый, ләкин ул аларга үзенең аеруча әһәмиятле хезмәтләрендә махсус бүлекләр багышлау җаен таба. Мәсәлән, 1880 елда дөнья күргән *«Кырык бакча»* китабының кырыгынчы бакчасы (бүлеге) — 296 мәкаль, 116 кыска җырны, 1884 елда нәшер ителгән *«Фәвакиһел-җөләса фил-әдә-*

бият» җыентыгының кырыгынчы раузасы (бүлеге) 27 табышмак, 117 кыска җыр, 3 бәет, 315 мәкаль һәм әйтемне үз эченә ала. Бу хезмәттә автор һәр жанрга кыскача билгеләмә бирә һәм күпчелек әсәрләрне фәнни шәрехләмәләр белән бастыра. К.Насыйри, фольклор материалларының шактыен русчага тәрҗемә итеп, «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләр»ендә *«Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре» (*1896) исеме белән бастыра. Ул 28 табышмак, 243 мәкаль һәм 145 җырдан гыйбарәт. Шул ук «Хәбәрләр»дә (1900) К.Насыйри П.А.*Поляков* белән берлектә язган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» хезмәтендә 11 татар халык әкиятен бастыра (тулырак кара: *Әкиятләр*). Хезмәттә татар әкиятләреңең башка халыкларның әкиятләре белән охшашлыгы күзәтелә. Бу исә татар мәдәниятеңең башка халыклар әдәбияты-мәдәниятеннән бер дә кайтыш булмавын раслый.

К.Насыйриның «*Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр»* исемле хезмәте — татар фольклорын өйрәнү тарихында беренче фәнни басма. Аның беренче бүлеге башлыча татар мифологиясеңең һәм тылсымлы әкиятләрнең сюжетларын һәм персонажларын классификацияләүдән гыйбарәт. Шунысы да игътибарга лаек: автор, хезмәтнең темасы таләп иткәнчә, мифик затларга характеристика бирү белән генә чикләнми, ә әкиятләрдәге кеше образларын да тәфсилле тасвирлый. Хезмәтнең икенче һәм өченче бүлекләрендә татар халкының күпсанлы *сынамышлары*, *ышанулары*, *ырымнары*, йолалары, им-томнары тирәнтен өйрәнелә. Басманың кереш өлешендә Петербург профессоры В.В.Григорьев аның әһәмияте турында болай дип яза: «Казан татары Каюм Насыйров үзенең бу мәкаләсе белән Казан татарларының ислам кабул иткәннәре аркасында хәзергә кадәр аз сакланып калган борынгы мәҗүси гореф-гадәтләрне тикшерүдә беренче тәҗрибә ясый... Фән ноктасыннан бу — шиксез, бик кызыклы, яхшы ук гыйльми хәзинә бирергә вәгъдә итә торган эш. Бу хакта Каюм Насыйров кебек тикшерүче мөселман татарлары арасында гына түгел, бәлки бөтен ислам дөньясында да чыкканы юк, дисәк, ялгышмаган булырбыз» (тулырак кара: *Мифология*, *Фольклор*).

К.Насыйриның татар фольклористика гыйлемен үстерүдәге төп эшчәнлеге, беренчедән, татар әдәби телен гамәлгә кую белән бәйле булса, икенчедән, халык авыз иҗатын өйрәнү аша аны пропагандалаудан, халкыбызның дөньяга карашын киңәйтергә омтылудан гыйбарәт. Татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыйнау гына да — гаять зур хезмәт, К.Насыйри исә аларны фәнни җирлектә өйрәнеп, билгеле бер системага салып бастырып чыгара. Аның турында татар фольклористикасына гыйльми, җәдиди юнәлеш биреп, аны шул нигездә үстереп җибәргән галим дип әйтергә була. К.Насыйри тарафыннан китерелгән әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, *табышмакларда* һәм татар халык авыз иҗатының башка үрнәкләрендә татар халкының үткен акылы, зирәклеге ярылып ята, тормыш-көнкүрешеңең үзенчәлеге чагыла.

Халык авыз иҗаты йогынтысында К.Насыйриның тарихи-иҗтимагый фикерләү сәләте, вакыйгаларны тасвирлау осталыгы формалаша. Татар халык иҗатын барлау, җыйнау һәм тикшерү белән бергә ул *тарих*, *археология* һәм *этнография* буенча да материаллар туплый башлый. Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә эшләгәндә, әлеге җәмгыять белән хезмәттәшлек иткән күренекле шәркыятьче галимнәр И.Ф.*Готвальд*, В.В.Радлов, төрки телләр галиме, этнограф Н.Ф.Катанов, тарихчы Н.А.Фирсов һәм башка галимнәр белән аралашу аңарда тарих фәненә зур кызыксыну уята һәм аны өйрәнүгә көчле этәргеч бирә. Әлеге галимнәр аңа тарихи материалларны җыю һәм тикшерү ысулларын өйрәтәләр, җыелган материалдан дөрес файдалану һәм билгеле бер системага салып өйрәнү тәртибенә төшендерәләр. К.Насыйри алар ярдәме белән татар тарихи дөньясын өйрәнүдә кайбер уңышларга да ирешә. Ул, татарлар арасында беренчеләрдән булып, Россия тарихы буенча китап *(«Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь»*, 1890) яза. Шулай ук Россия империясе, шул исәптән Казан губернасы һәм илнең башка төбәкләре турында еллык календарьларында тарихи мәкаләләр бастыра. Алар арасында Казан, Зөя шәһәрләре, татар авыллары хакында тарихи *риваятьләр* дә бар. Ш.Мәржанидән аермалы буларак, К.Насыйри тарихны халык күзлегеннән чыгып өйрәнергә-тикшерергә һәм аңлатырга омтыла.

Мөгаллимлек һәм фәнни-гамәли эшчәнлек алып бару белән беррәттән ул татар халкын төрле яктан өйрәнү максаты белән еш кына Казан һәм Зөя тирәсендәге авылларда була. Мәкәржә ярминкәсенә, Уфага һәм берничә мәртәбә Мәскәүгә бара. 1893 елның җәендә аның Оренбург шәһәренә һәм *Сәгыйд бистәсенә* сәфәр кылуы билгеле. Бу турыда язылган сәяхәтнамәсе дә бар. Шул сәфәрләре вакытында ул татар тарихы, этнографиясе, археологиясе, *эпиграфикасы* буенча риваятьләр, шәҗәрәләр һәм башка материаллар туплый, аларның бер өлешен календарьларында бастыра.

К.Насыйриның *Казан* тарихына караган язмалары аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, бер риваятендә ул 16 йөзнең 1 нче яртыларында яшәгән Шаһгали ханның, Мәскәүгә сатылып, Казан мәмләкәтенә, шул исәптән үз халкына хыянәт итүе, ахыр чиктә татарларның, дәүләтчелектән мәхрүм ителеп, коллыкка төшүе турында яза. Аның Аксак Каратун (Лука Конашевич), Пугачёв яулары хакындагы риваятьләре мәгълүматларга байлыгы белән аерылып тора. К.Насыйри Казан тарихы белән беррәттән Казан губернасы Зөя һәм Цивильск өязләре татар авылларының (Ачасыр, Бакырчы, Борнаш, Борындык, Мамадыш, Мулла Иле, Рәсбуга, Шигали, Югары Шырдан һ.б.) тарихы хакында да мәкаләләр яза. Бу уңайдан ул халык авыз иҗатында сакланган материалларны, каберташ язуларын, төрле шәҗәрәләрне, кулъязма һәм басма китапларны ныклап өйрәнә.

К.Насыйри — татар гыйлеме дөньясында милли этнографияне яңача нигезләп, үстереп җибәргән галим. Аның бу өлкәдәге хезмәтләре аңа кадәрге сәяхәтче галимнәрнең этнографик күзәтүләреннән фәнни гомумиләштерүләренең сыйфатлы булуы, теге яки бу мәсьәләгә этрафлы аңлатма бирер-

гә омтылышы белән аерылып тора. Ул фольклорга этнография фәненең бер тармагы буларак кына карамый, аны аерым фән дәрәҗәсендә өйрәнә. Аның татар этнографиясенә караган хезмәтләрендә халкыбызның тормыш-көнкүреше (йорт-җире, кием-салымы, ашау-эчү), гореф-гадәтләре (балага исем кушу, бәби туе, яучылау, туй уздыру, матәм һәм башка йолалар) яктыртыла. К.Насыйри, беренчеләрдән булып, ашау-эчү турында «*Иршад әл-әтбиха*» (1894) исемле китап яза. Бу китапта катлаулы ашамлык төрләрен әзерләү ысуллары күрсәтелә, 19 йөз татар аш-су традицияләренең бай, үзенчәлекле тасвирламасы бирелә (тулырак кара: «*Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча)*»).

К.Насыйри шулай ук, татар халык авыз иҗатыннан, Көнчыгыш һәм рус әдәби әсәрләре тәрҗемәләреннән файдаланып, милли әдәбиятны баета. Тәрҗемәче буларак та, зур уңышларга ирешә. Урта гасырлар Шәрекъ классикасы чәчмә әсәрләрен тәрҗемә иткән вакытта, мәгърифәтче аларның оригиналларын татарчага төгәл күчереп, аерым кыскартулар ясап кына калмый, төп текстка теге яки бу дәрәҗәдә тиешле үзгәрешләр дә кертә. Шул ук вакытта аның тәрҗемәләрендә вакыйга-хәлләрне урыны-урыны белән татар халкының тормыш-көнкүрешенә яраклаштыру да күзәтелә. Тәрҗемә остасы буларак, ул төрек язучысы Зыяддин Сәед Яхъяның күренекле мөселман философы, энциклопедист галим, табип Әбугалисина турындагы «Кәнҗинәи хикмәт» («Хикмәт хәзинәсе», 1865) исемле китабын 1872 елда төрекчәдән татарчага тәрҗемә итә. Аның берничә басмада дөнья күргән «*Әбугалисина кыйссасы*» татар халкының рухи-мәдәни үсешенә, гуманистик тәрбиясенә зур йогынты ясый. 1896 елда К.Насыйриның «*Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан*» әсәренең тәрҗемәсе басылып чыга. Әсәрдә патша кызы белән шаһзадәнең мәхәббәт тарихы үзәккә алынып яктыртыла. Тәрҗемәченең «*Кырык вәзир кыйссасы*» (1868) әсәрендә төрле вакыйгалар ярдәмендә мисал-дәлилләр белән гаделлекнең тантана итүе чагылдырыла. Шулай ук әдипнең тәрҗемәләре арасында «Кабуснамә» (1881, кара: «*Кабуснамә тәрҗемәсе*») китабы аерым игътибарга лаек. 1886 елда ул шәркыятьче галимә *Гөлнар ханым* (О.С.Лебедева) тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп бастырыла. К.Насыйри әдәби тәрҗемәләрен китап итеп кенә чыгарып калмый, ул аларны төрле әсәрләрендә дә урнаштыра («Тәрбия китабы», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият», «Кырык бакча» һ.б). Аның халык авыз иҗаты үрнәкләреннән, әдәби әсәрләрдән (хикәяләр, новеллалар, шигырьләр) гыйбарәт энциклопедик характердагы «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» исемле дидактик хезмәте татар әдәбияты тарихында аерым урын алып тора. Тәрҗемә эшчәнлеге белән бәрәттән әдип-галим татар әдәбиятын фәнни җирлектә дә өйрәнүен дәвам итә. Әдәби ядкәрләргә, татар язучыларына (Габдерәхим Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый һ.б.) һәм аларның иҗатларына багышланган хезмәтләрендә фәнни әһәмияткә ия күзәтүләр ясый. Мәсәлән, Г.Кандалый шигырьләренең лирик асылын өйрәнеп, аларның поэтик яктан «яхшы төзелү»ен искәртә... Теге яки бу әдәби әсәрнең структур үзенчәлекләре,

идея-эстетик әһәмияте, тәрбияви кыйммәте, шулай ук әдәбиятның башка мәсьәләләре яктыртылган фәнни хезмәтләре аның әдәбият буенча белем дәрәҗәсен күрсәтә.

К.Насыйри татар халкының белемен үстерү максатында төрле фәнни-популяр хезмәтләр дә тәрҗемә итеп бастыра. Алар арасында «Буш вакытларда укырга сүзләр» (1867) җыентыгы аеруча әһәмияткә ия (кара: *«Буш вакыт»*). Ул аны, рус язучысы һәм педагогы К.Д.Ушинскийның башлангыч сыйныф укучылары өчен рус телендә язылган «Балалар дөньясы» (1861) фәнни-популяр һәм әдәби-педагогик хрестоматиясе мәкаләләрен тәрҗемә итеп, күпмедер кыскартып һәм үзгәрешләр кертеп, сәнгатьчә алым-чаралар белән баетып эшли. Балалар өчен махсус татар телендә язылган, укырга кызыклы итеп төзелгән әлеге китап алга таба да фәнни-әдәби әсәрләр иҗат итүгә юл ачкан тәүге басма булып тора. Ул тулысынча диярлек европачыл җәдиди-мәгърифәтчел карашлар кысасында язылган.

К.Насыйри дин мәсьәләләрендә дә киң карашлы, тәрбиягә багышланган хезмәтләрендә халык рухын, әдәп-әхлак кануннарын яхшы тоеп эш итүче галим буларак сыйфатлана. Моның шулай булуын *«Мәҗмәгу әл-әхбар»* китабы (1859) раслый. Мәгърифәтченең мөселман дине тәгълиматы турында 1859 елда язылган *«Гакаид рисаләсе»* китабы 1867 елда гына дөнья күрә. Аның ислам өйрәтүләренә караган берничә хезмәте (*«Мохтәсар тәварих әнбия...»*, *«Утыз вәгазь»*, *«Җәваһир әл-хикәят»* һ.б.) даими рәвештә нәшер ителә (тулырак кара: *Дини гыйлем*).

К.Насыйри, халык педагогикасына, күптөрле язма чыганакларга нигезләнеп һәм Шәрекъ дөньясының фикер ияләре әсәрләреннән файдаланып, тәрбия һәм әхлак турында хезмәтләр яза. Аларда ул белем-тәрбия бирүнең берлеген һәм дәвамчанлыгын, әхлакый һәм гуманистик тәрбиянең мөһимлеген, акыл һәм тәҗрибәнең үзара тыгыз бәйләнештә булуын яктырта, «Һәрбер нәрсәнең, — ди ул, — чиге бардыр. Әмма гакылның чиге вә соңы юктыр... Гакыл вә тәҗрибә бер-берсенә ярдәмче булмакта җир белән су кебектер. Мәгълүм ки, су белән җир бер-берсеннән башка бер нәрсә дә үстерә алмыйдыр...». Галим фикеренчә, ата-ана, мөгаллим үз-үзләрен тотышлары, кылган гамәлләре белән балага тәрбиялелек үрнәге булып торырга тиеш. «Балалар һәрни күрсә, һәрни кылса, ата-анасыннан күреп кыладыр. Атасында, анасында һичбер кимчелек күрмәй үссен, чөнки баланың табигате шундый ки, күбрәк олугларга иярәдер», — ди ул (шулай ук кара: *Гаилә мөнәсәбәтләре*).

К.Насыйри үзенең хезмәтләрендә тәрбия сабакларын еш кына татар халык авыз иҗатыннан, көндәлек тормыштан гыйбрәтле мисаллар, җанлы сюжетлар аша бирә. Бу исә үгет-нәсыйхәтләрнең үтемлелеген, тәэсирлелеген тагын да арттыра. Ул тәрбия эшендә музыка һәм сүз сәнгатенең әһәмиятенә басым ясый. Аның фикеренчә, җыр-музыка «уй-фикерне саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне (холыкны) йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, куркакны баһадирландырыр, саранны юмартландырыр». Икенче бер урында мондый юлларны күрергә мөмкин: «Көйләп укымак яки шигырь

әйтмәк гүзәлләрдән янә гүзәл нәрсәдер». Аның күпкырлы тәрбияви хезмәтләрендә, беренче чиратта, физик яктан сәламәт, көр күңелле, белемле балалар тәрбияләү омтылышы сизелә. *«Әхлак рисаләсе»*нең «Гыйлем вә наданлык» исемле беренче бүлегендә әдип балаларга болай дип мөрәҗәгать итә: «Әй газиз бала, агаһ бул, әдәмгә иң әүвәл бигрәк кирәк вә бигрәк лазем нәрсә гыйлемдер, вә гыйлем дигәнемез белмәгән нәрсәне сорашып белмәктер. Вә наданлык дигәнемез белмәклеге лазем булган нәрсәне белмәссезлектер. Бу наданлык кешене игътибардан чыгара торган нәрсәдер, вә хәйван дәрәҗәсенә кертә торган сыйфаттыр, кайда барса да надан кешенең кадере юктыр!». Шулай ук аның хезмәтләрендә һәм педагогик карашларында балаларга нинди дә булса һөнәр өйрәтү кирәклеге ассызыклана. К.Насыйри яшь буынны гыйлем алу белән бергә нинди дә булса һөнәргә дә өйрәнергә чакыра. Бу уңайдан «Китаб-әт-тәрбия» (1891, кара: *«Тәрбия китабы»*) китабында ул болай дип яза: «Әй җаннарым-угланнарым, нәсихәтне ишетегез — һөнәр үгрәнегез. Дөньяның милкенә вә дәүләтенә ышанырга ярамас... Һөнәр — бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләттер, һөнәр иясе әгәр дәүләттән төшсә дә кайгы юк... Әй угыл, син дә һөнәр үгрән, тәрбия үгрән, гыйлем үгрән», яки «Кирәк ниндәен һөнәр булса да һөнәрнең артыгы юк», «һөнәр арттырырга иҗтиһат кыл, чөнки һөнәрсез кешенең беркемгә дә файдасы булмас, бәлки үзенә дә файдасы юк». Мәгърифәтченең әлеге карашлары аның тәрбия системасында төп кыйммәт булып торалар. Ул балаларны акыллы, әдәпле булырга өнди. «Олуглык гакыл белән, әдәп белән, әмма нәсел белән, нәсәп белән түгелдер», «әгәр дә бер адәм белән мөсәхабәт кылсаң, аның гакылына кара, диненә карама. Чөнки аның дине үзенә фәкать, әмма гакылы үзенә һәм сиңадыр» дигән карашлары, тәрбия сабаклары шактый әсәрләрендә әдәби образлар аша чагылдырыла, гыйбрәтле мисаллар, тормышчан сюжетлар ярдәмендә яктыртыла. Бу исә үгет-нәсыйхәтләрнең тәэсирен тагын да арттыра (шулай ук кара: *Балалар әдәбияты*).

Гомумән алганда, К.Насыйри татарларның физик, рухи һәм әхлакый яктан сәламәт, камил булуларын тели, милләтне белемле һәм күркәм гадәтле итәргә омтыла. Эчкечелеккә, тәмәке тартуга һәм башка шундый ямьсез сыйфатларга тискәре мөнәсәбәтен белдерә, бу күренешләрне кешеләрне һәлакәткә илтүче кайгы-хәсрәт чыганагы дип саный: «Эчемлек эчә торган кеше һәрбер чәркәне эчкән саен үзен генә үтермидер, бәлки бөтен нәселен үтерәдер...». Аның еллык календарьларында әлеге проблема үзәккә алынып яктыртыла, үгет-нәсыйхәт характерындагы дистәләгән мәкаләсе дөнья күрә. Ул, татар халкы арасында таралган эчкечелекнең һаман саен артуына борчылып, сигез шигырьдән торган поэма яза, анда исереклек галәмәте белән кылынган төрле затсыз гамәлләр сурәтләнә һәм аларда авторның нәфрәт катыш борчу-сагышы сизелә (кара: *«Исереклек заманы»*).

К.Насыйри халыкны агарту максатында «Таң йолдызы» исемле газета чыгару хыялы белән яши, әмма патша хөкүмәте аңа бу ниятен гамәлгә ашырырга рөхсәт бирми (тулырак кара: *Вакытлы матбугат*). Шулай да

ул халыкка белем-мәгърифәт таратуның башка бер ысулын таба: еллык өстәл календаре (горрәнамә) чыгара башлый. 1871 елдан 1897 елга кадәр нәшер ителгән, татар халкының милли-мәдәни тормышында көтелмәгән һәм зур яңалык булган бу календарьлар даими рәвештә халыкның көндәлек тормышыннан яңалыклар, мөһим тарихи-иҗтимагый хәбәрләр белән таныштыра; аларда шулай ук төрле һөнәрләргә өйрәтә торган язмалар, күңел ачу характерындагы материаллар, әкиятләр, мәкальләр, җырлар, Шәрекъ авторларыннан тәрҗемәләр һәм мәгърифәтченең үз әсәрләреннән өзекләр урын ала. Календарьның беренче чыгарылышында ук К.Насыйри аның ахыргы битләрендә халык өчен әһәмиятле булган «Халык арасында тәҗрибәләр буенча көн вә һава үзгәрүнең галәмәтләре бәянында» исемле сәхифә ача. Анда, татар халкы арасындагы төрле сынамышлардан чыгып, һава торышы, авыл хуҗалыгы һәм өй эшләре, бөртекле ашлыкларның уңу-уңмавы һәм башка күренешләр турында фаразлар китерелә. Шулай ук аларда ашау-эчү, крахмал, серкә (уксус) һ.б.ны әзерләргә, җиләк-җимеш киптерергә, дару үләннәрен дөрес җыярга һәм алар белән дәваланырга һәм башка шуның ише гамәлләр генә өйрәтелеп калмый, татарларның белемен арттыру ниятеннән гуманитар (тел белеме, фольклор, тарих, әдәбият, этнография, демография, хокук һ.б.) һәм табигыять (арифметика, *астрономия*, ботаника, география, *медицина*, физика, химия һ.б.) фәннәренең төрле тармакларына караган мәгълүматлар да бирелә (тулырак кара: *Каюм Насыйри календарьлары*). Шул рәвешчә, чирек гасыр дәвамында чыгып килгән календарьлар татар тормышына билгеле бер дәрәҗәдә уңай йогынты ясый, киң гавамны күздә тотып нәшер ителгән бу басмалар татар зыялылары белән беррәттән гади кешеләр арасында да зур популярлык казана, ул Россия буенча, беренче чиратта татарлар яши торган төбәкләрдә, аерым экземплярлары Урта Азия һәм Кавказ арты мөселманнары арасында да киң тарала (кара: Әбусуфьян *Акаев*). Галим аларны, нигездә, үз акчасына һәм өлешчә аерым эшмәкәрләрнең иганәләре хисабына чыгара. Алга таба календарьлар җирлегендә татар телендә вакытлы матбугат барлыкка килә.

Гыйльми-әдәби эшчәнлеген мәдрәсәдә укыганда ук башлап җибәргән К.Насыйриның үзе исән чакта татар һәм рус телләрендә төрле күләмдәге 40 лап китабы һәм берничә дистә мәкаләсе дөнья күрә. Кайбер китаплары берничә тапкыр басыла. Китап белеме галиме, библиограф Әбрар *Кәримуллин* исәбе буенча, К.Насыйриның үзе исән чагында гына да йөзгә якын китабы басылып чыга. Аның тормыш юлын һәм иҗат эшчәнлеген өйрәнгән Мөхәммәт *Гайнуллин*, беренчеләрдән булып, әдипнең татар телендә дөнья күргән аерым хезмәтләренең библиографик күрсәткечен төзи. 40 исемнән торган бу күрсәткеч мәгърифәтче галимнең тел белеме, әдәбият, арифметика, геометрия, тарих, география, этика, рус теленә өйрәтү, зәркәнчелек һәм слесарьлык эшләре буенча язылган хезмәтләрен үз эченә ала (тулырак кара: *Каюм Насыйриның тормышы һәм иҗаты хакында библиография)*. К.Насыйриның вафатыннан соң бик күп кулъязмалары һәм

хатлары кала (кара: *Каюм Насыйриның кулъязмалары, Каюм Насыйриның хатлары*). Алар Казан федераль университеты китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә*, ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының *Язма мирас үзәгендә* һәм башка оешмаларда саклана. К.Насыйриның арифметика (математика), астрономия, ботаника, география, геометрия, дин белеме, игенчелек, кулинария, медицина (анатомия, физиология, гигиена), тел белеме, хокук һәм башка фәннәр буенча язган китаплары һәм аерым мәкаләләре татар халкының берничә буыны тарафыннан уку-укыту әсбабы сыйфатында файдаланыла. Аның хезмәтләре бүген дә әһәмиятен җуймый, ул күтәргән мәсьәләләр безнең көннәрдә дә актуаль.

К.Насыйриның энциклопедик масштабтагы эшчәнлеге, беренче чиратта, замандашлары — шәркыятьче галимнәр В.В.Григорьев, В.Д.*Смирнов,* төрки телләр галиме Н.Ф.Катанов тарафыннан югары бәяләнә. Мәгърифәтче галимнең иҗатына аеруча Н.Ф.Катанов зур игътибар бирә, ул аның дистәдән артык әсәренә рецензия яза (кара: *Бәяләмә*, «*Деятель*» газетасы). Язучы Фатих *Әмирхан*: «Иң әүвәл татарларга үзләренең бер телләре бар икәнен белдертер өчен, К.Насыйри «Ләһҗәи татари» вә «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» тәэлиф итүче вә ул ук, иң әүвәл, әсәрләрен татарча яза башлап, һәр язу таныган кеше истифадә итәрлек тарызда ясаучы...», — ди (1908). Тел галиме Җамал *Вәлиди* «Каюм әфәндегә кадәр татар теле дигән бер тел юк иде. Телебезне иң әүвәл бер телгә хисаблап аның да кагыйдәсе барлыгын, башка телләрдән ким булмавын вә хәтта артыклылары булуын дәгъва вә исбат итүче улдыр», — дип яза (1912) һәм «Каюм Насыйри иң элек безнең татарлыгыбызны аңлады һәм аны үзенең әсәрләре илә башкаларга да аңлатмакчы булды», — дип ассызыклый. Ул аны «татар әдибе» дип зурлый. Язучы Галимҗан *Ибраһимов* К.Насыйрины Шәрекътән Гаребкә (Көнбатышка, Европага) юл яручы, беренче сукмакны салучы «бөек реформатор» дип атый. Ул: «Каюм бабаның хезмәте гыйлем дөньясы өчен яңа кануннар табып чыгаруда түгел, бәлки бәйнәлмиләл гыйльми мәгълүматны татар халкына башлап бирүдә... Ул бездә Европа гыйлемнәрен беренче популяризатор иде», — ди (1926). Мәшһүр тел галиме-тюрколог Н.К.*Дмитриев* татар галименең фәнни-иҗади эшчәнлеген Италиянең күпкырлы галиме, танылган рәссамы, нәкышьчесе Леонардо да Винчи, беренче бөек рус галиме, табигыять фәннәре белгече, филолог М.В.Ломоносов хезмәтләренә тиңли: «Алар барысы да энциклопедистлар булганнар, нинди дә булса бер фән яки сәнгать кысаларында гына калмаганнар. Алар үзләренең кыска гына гомерләрендә тормышта кирәкле барлык фәннәргә һәм сәнгатьләргә дә нигез салып калдырырга ашыкканнар... Кем булган Ломоносов: физикмы, механикмы, тел белгечеме, әдәбиятчымы? Леонардо да Винчи... һәм Каюм Насыйри кем булган дигән сорауга җавап бирү дә шактый кыен...». Гаяз *Исхакый* аны яңа дәвер әдәбиятының «атасы» дип атый, чөнки ул — рухи-әхлакый һәм идея-эстетик тәрбия биргән күп кенә күренекле әсәрләрне татар укучыларына татар телендә ирештергән шәхес. Татар

укучысының образлы фикерләвен, зәвыгын, туган телнең эчке мөмкинлекләрен истә тотып эш иткән К.Насыйриның тәрҗемә эшчәнлеге дә югары бәяләнә. Шәрекъ халыклары тарихын, ислам гыйлемен өйрәнүче француз шәркыятьче галимәсе Шанталь *Лемерсье-Келькеже* аның турында болай ди: «Иң әүвәл яктылыкка юлны Каюм Насыйри ачмаса, дөньяда Габдулла Тукай, Шәехзадә Бабич, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакый, Мәҗит Гафури кебек йолдызлар якты яна алмас иде».

***

К.Насыйри тормышының соңгы елларында үз акчасына туган авылы Югары Шырданда мәчет төзетергә уйлый. Авылдашларының икенче Җамигъ мәчет төзүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән үтенечләре буенча 1901 елның 20 июлендә уңай карар кабул ителә. К.Насыйри мәчет төзү чыгымнарын тулаем үз өстенә ала һәм акча бүлеп бирә, әмма бу мәчетне күрү аңа насыйп булмый. Ул 1902 елның 3 сентябрендә (искечә 21 августында) Казанда туганы Мөхәммәтбәдигъ *Хөсәенов* йортында вафат була. Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнә (тулырак кара: *Каюм Насыйриның вафаты*, *Каюм Насыйриның кабере*).

Тәрҗемәи хәлен һәм тормышын өйрәнү. К.Насыйриның иҗатын үзе исән вакытта фәнни яктан бәяләүчеләр бик аз була, аларның да күпчелеген рус шәркыятьче галимнәре (И.Ф.Готвальд, В.В.Григорьев, К.Г.*Залеман*, Н.И.Ильминский, Н.Ф.Катанов, О.С.Лебедева, П.П.Масловский, В.В.Радлов, Г.С.Саблуков, В.Д.Смирнов һ.б.) тәшкил итә. К.Насыйри вафатыннан соң «Тәрҗеман» газетасында (1902), татарлар арасында беренче булып, язучы Гаяз Исхакыйның «Габделкаюм әфәнденең вафаты» исемле некрологы басыла. Анда мәгърифәтченең тәрҗәмәи хәле һәм гыйльми эшчәнлеге яктыртыла, татар теле өлкәсендәге хезмәтләре югары бәяләнә.

К.Насыйри вафатына ун ел тулуга бәйле рәвештә татар халкы тарихы турында беренче китаплар күренә башлауга, киң җәмәгатьчелек арасында аның күпкырлы иҗаты һәм тәрҗемәи хәленә карата кызыксыну уяна. Әйтик, 1912 елда «Йолдыз» газетасында тарихчы Габделбари *Батталның* К.Насыйригa багышланган «Телебез» мәкаләсе басыла. Анда мәгърифәтченең халыкка аңлаешлы әдәби тел булдыру юнәлешендә дәвамлы һәм нәтиҗәле эшчәнлек алып баруы турында әтрафлы яктыртыла. Мәкалә авторы: «Үз арабыздан чыгып, үз телебезне тергезү нияте белән кулына каләм тоткан затларыбызның иң олугысы Габделкаюм әл-Насыйри абзыйдыр. Аның хезмәтләре татар теленең фән теле була алуына ышандыралар», — дип басым ясый. Шул ук вакытта тарихчы К.Насыйри кебек олуг затка матбугат битләрендә игътибарның булмавына, татар милләте арасында исеменең онытыла баруына ачынып гарьләнә һәм «Шура» журналы мөхәрририятенә бу уңайдан кисәтү ясый. Әлеге вакытлы матбугатның мөхәррире Ризаэтдин *Фәхретдин*, аңа җавап итеп, мәгърифәтче турында бастырырга материал юклыгын әйтә. К.Насыйри турында азмы-күпме мәгълүматлы кешеләр булса, журналга җибәрүләрен үтенә. Нәтиҗәдә, «Шура»ның

1912–1913 елгы саннарында мәгърифәтче галим турында бер дистәдән артык хатирә, биографиясе-шәҗәрәсе, туганнары турында мәкаләләр дөнья күрә (тулырак кара: *Истәлекләр*).

Совет хакимияте чорында, Татарстан Җөмһүрияте барлыкка килгәч, К.Насыйри темасы яңадан күтәрелә. 1922 елның сентябрендә, каты ачлык китергән зыяннан арыну чорында, *Гыйльми үзәк* К.Насыйриның вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте белән аны искә алу чаралары үткәрү турында карар кабул итә. Бу эштә татар теле һәм әдәбияты белгечләре, язучылар, тарихчылар, дәүләт эшлеклеләре Галимҗан Ибраһимов, Шаһит *Әхмәдиев*, Җамал Вәлиди, Хуҗа *Бәдигый*, Гали *Рәхим*, Газиз *Гобәйдуллин* һ.б. актив катнаша. Татарстанда үткәрелгән искә алу чаралары белән берәттән К.Насыйриның тәрҗемәи хәлен һәм иҗатын өйрәнү эшләре дә алып барыла. Нәтиҗәдә, 1922 елда галимнең мирасы турында *«Каюм Насыйри мәҗмугасы»* исемле беренче фәнни җыентык дөнья күрә. Анда Г.Ибраһимовның К.Насыйриның татар мәгърифәтчелек фикерен үстерүдәге фидакарь хезмәте яктырылган «Каюм Насыйриның тарихи урыны» исемле мәкаләсе аерым игътибарга һәм ихтирамга лаек. Бу мәкалә соңрак К.Насыйри иҗатын өйрәнүче совет галимнәре өчен «үзенчәлекле маяк» булып хезмәт итә (шулай ук кара: *Татар мәгърифәтчелеге*).

1925 елның февралендә, К.Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан, Татарстан Җөмһүрияте җитәкчелеге һәм Гыйльми үзәк тарафыннан төрле тантаналы чаралар һәм форумнар уздырыла, бу юнәлештә фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла. Әлеге чараларда Фатих Әмирхан, Гыйлемдар *Баембитов*, Хажи *Габидуллин*, Галимҗан Ибраһимов, Нәкый *Исәнбәт*, Мөхетдин *Корбангалиев*, Әхмәтһади *Максуди*, Мөхәммәт *Парсин*, Гали Рәхим, Шәйгәрдан *Шәймәрданов* һәм башка галимнәр, дәүләт эшлеклеләре катнаша. Үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә К.Насыйриның тарих, археология һәм этнография буенча кулъязмалары һәм әсәрләре *«Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга»* (1926) дип аталган җыентыкта дөнья күрә. Бер үк вакытта, 1920 елларда, Татарстан газета-журналларында («Безнең юл», «Вестник научного общества татароведения», «Известия ТатЦИК», «Кызыл Татарстан» һ.б.) К.Насыйриның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында мәкаләләр һәм хәбәрләр бастырыла.

К.Насыйри шәхесенә 1945 елда, тууына 120 ел тулу уңае белән, кабат әйләнеп кайталар. 1945 елның мартында, Бөек Ватан сугышының соңгы айларында, Мәскәүдә һәм Казанда СССР Фәннәр академиясенең К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган Гыйльми сессиясе уздырыла. Аның эшендә Мәскәүдән — күренекле тел галимнәре: академик С.П.Обнорский, мөхбир әгъзалар Н.К.Дмитриев, М.Ә.Фазлуллин; Казаннан — Җамал *Вәзиева*, Н.И.*Воробьёв*, Мөхәммәт *Гали*, В.М.*Горохов*, Мөхәммәт Гайнуллин, Хәйри *Гыймади*, Латыйф *Җәләй*, Фатих *Мөхәммәдъяров*, Шиһабетдин Рамазанов, Рабига *Хәкимова*, Вәли *Хангилдин*, Хәмит Ярми һ.б. катнаша. Н.К.Дмитриев форумда мәгърифәтчегә багышланган чыгышында болай ди: «Һәр халыкның тормышында, аерым бер кеше тормышындагы кебек,

үз язы була. Каюм Насыйри аны беренчеләрдән булып тоя һәм бөтен иҗатын шуңа багышлый». 1948 елда *«Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)»* дөнья күрә. Гыйльми сессия материалларында 19 йөздә Россия империясендә, аеруча әдәбият-мәдәният дөньясында барган яңарыш алгарышлары яссылыгында К.Насыйриның татар мәдәниятен, мәгарифен һәм әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше яктыртыла, татар халкын әдәби-мәдәни агартудагы роле күрсәтелә. Җыентыкта шулай ук Мөхәммәт Гали һәм Хәмит Ярми тарафыннан К.Насыйриның авылдашларыннан язып алынган *истәлекләр* урнаштырыла.

Бу форумнан соң СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәрләре К.Насыйриның сайланма җыентыкларын әзерләп чыгару эшен дәвам итәләр. 1975 елга, мәгърифәтче әдипнең тууына 150 ел тулганчыга кадәр, берничә «Сайланма әсәрләр» җыентыгы (1945, 1953, 1956 (икенче басмасы, шул ук: *«Әсәрләр»*, 1971), 1974–1975 (ике томда) еллар) дөнья күрә. Шул юбилей уңаеннан Казанда Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан университеты, Казан педагогия институты тарафыннан *«Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри»* исемле конференция уздырыла. Анда Мәскәүдән тел галиме, төрки телләр белгече А.Н.Кононов, Дагстаннан әдәбият галиме С.Х.*Акбиев*, Казаннан Искәндәр *Абдуллин*, Сәләм *Алишев*, Рашат *Әмирханов*, Ялкын *Әхмәтгалиева*, Дания *Баһаветдинова*, Мәсгуд *Гайнетдинов*, Мөхәммәт Гайнуллин, Мирфатыйх *Зәкиев*, Әбрар Кәримуллин, Хуҗиәхмәт *Мәхмүтов*, Сәвия *Михайлова*, Мидхәт *Мөхәррәмов*, Рәүфә *Уразманова*, Камил *Фасиев*, Фазыл *Фасиев*, Равил *Фәхретдинов*, Вахит *Хаков*, Шифа *Ханбикова*, Әнвәр *Хәйри* һәм башка галимнәр докладлар белән чыгыш ясыйлар.

2003–2006 елларда К.Насыйриның дүрт томлы сайланма әсәрләренең басылып чыгуы галимнең күпкырлы иҗаты белән тулырак танышу мөмкинлеге бирә. Бу басмалар — мәгърифәтченең иң тулы сайланма әсәрләре җыентыгы. Мәсгуд Гайнетдинов һәм Хуҗиәхмәт Мәхмүтов — К.Насыйриның гарәп графикасындагы аерым текстларын гамәлдәге татар язуына күчерүче һәм кереш мәкалә авторлары.

2015 елда К.Насыйриның тууына 190 ел тулу уңаеннан Казанда ТР Фәннәр академиясенең Тарих институты тарафыннан *«Урта һәм югары белем бирү системасында татар телендә укыту: тарих, заманчалык һәм алгарышлар»* исемендә конференция уздырыла. Анда, башлыча, Казан федераль университеты, ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре (Г.Г.*Батыршина*, Р.Х.Шәймәрданов, М.М.Шәкүрова, Р.Р.Хөснетдинов һ.б.) катнаша (шулай ук кара: *Каюм Насыйриның юбилейлары*).

К.Насыйрига багышланган төрле форумнар аның биографиясен һәм күпкырлы иҗатын өйрәнүгә зур этәргеч булып торалар. Бу фәнни-иҗади эшчәнлектә, күргәнебезчә, 20 йөзнең 2 нче яртысы – 21 йөз башында Татарстанның югары уку йортлары һәм фәнни-тикшеренү институтлары, аерым

алганда, Казан университеты (Әбрар Кәримуллин, Мостафа *Ногман*, Резеда *Ганиева*, Мөхәммәт *Мәһдиев*, Ибраһим *Нуруллин*, Альберт Фәтхи, Вахит Хаков, Әлфия *Юсупова* һ.б.), Казан педогогия институты (В.М.*Беркутов*, Таһир *Корбанов*, Якуб *Ханбиков*, Әнвәр *Хуҗиәхмәтов* һ.б.) һәм Тел, әдәбият һәм тарих институты (соңрак Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) (Хатип *Алишев*, Мәсгут Гайнетдинов, Мөхәммәт Гали, Латыйф Җәләй, Мирфатыйх Зәкиев, Фатыйма *Ибраһимова*, Рәмил *Исламов*, Хәлиф *Курбатов*, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Хисам *Мөхәммәтов*, Шиһабетдин Рамазанов, Резеда *Рәхимова*, Гали *Халит*, Шифа Ханбикова, Вәли Хангилдин, Заһир *Шәйхелисламов*, Хәмит Ярми һ.б.), Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты галимнәре зур активлык күрсәтәләр.

Шулай ук К.Насыйриның юбилейлары уңаеннан «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан», «Ватаным Татарстан» газеталарында, «Коммунист Татарии», «Татарстан», «Совет әдәбияты», «Казан утлары», «Совет мәктәбе», «Мәгариф» журналларында аның турында төрле әчтәлектәге мәкаләләр дөнья күрә.

К.Насыйри, галим һәм нашир буларак, Татарстанда фәнни-гамәли яктан иң өйрәнелгән әдипләрнең берсе. Галим-әдип эшчәнлегенең төрле тармаклары яктыртылган дистәләгән монография языла, диссертацияләр яклана, йөзләгән мәкалә дөнья күрә. Шуңа да карамастан, энциклопедист галимнең мирасы әле дә өйрәнү-тикшерүне һәм дөньяга чыгаруны таләп итә, чөнки аның кайбер язмалары, мәсәлән, календарьларындагы текстлары гамәлдәге татар язуына күчерелмәгән, кулъязма хәлендәге хезмәтләре дә байтак, шулай ук кайбер әсәрләре (иң күләмлесе — «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият») тулысынча басылмаган.

Исемен һәм күпкырлы эшчәнлеген мәңгеләштерү. Бу гамәл Совет чорында башлана. 1925 елда Татарстан хөкүмәте тарафыннан Гыйльми үзәктән килгән тәкъдим нигезендә Казан шәһәрендәге Татар бистәсенең бер урамына (кара: *Каюм Насыйри урамы*), Казан татар укытучылар мәктәбенең дәвамчысы булган Казан татар педагогия техникумына, 2021 елда *Сиксәненче мәктәпкә* К.Насыйри исеме бирелә. Соңрак аның исеме белән Татарстанның башка торак пунктлары урамнары да аталып йөртелә башлый.

Казанда үз өе булмау сәбәпле, К.Насыйрига еш кына яшәү урыннарын алыштырып торырга туры килә (кара: *Каюм Насыйриның яшәү урыннары*). Казанда вафаты алдыннан яшәгән йортта 2002 елда *Каюм Насыйри музее*, аңа кадәр, 1997 елда, Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында К.Насыйри исемендәге *Архитектура-этнография комплексы* ачыла. 2015 елда «Бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган җире — тарихи авыл — Кече Шырданны торгызу» хәйриячелек фонды (оештыручысы — «Акведук» ҖЧҖ директоры А.Н.*Гобәйдуллина*) нигезләнә.

2014 елда Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында *Каюм Насыйри институты*, Россиянең кайбер шәһәрләрендә, Башкортстанда, Әзәрбайҗанда, Казакъстанда,

Кыргызстанда, Үзбәкстанда, Төркиядә һәм башка җирләрдә әлеге институтның үзәкләре ачыла.

1988 елдан Татарстан халык мәгарифен үстерүгә шәхси хезмәтләре белән зур өлеш керткән укытучылар, мәгариф һәм фән хезмәткәрләре, шулай ук педагогик коллективлар ел саен *Каюм Насыйри бүләге* белән бүләкләнәләр.

Шулай ук мәгърифәтченең юбилейлары уңаеннан чыгарылган *Каюм Насыйри маркасында* (1952), Истәлек медалендә (2005), *Юбилей тәңкәсендә* (2025), *«Каюм Насыйри»* драмасында (1945), *«Каюм коесы»* поэмасында (1997) аның исеме мәңгеләштерелә.

К.Насырийның фоторәсемнәре булмау сәбәпле, рәссамнар һәм сынчылар аның сурәтен һәм образларын ике дистәдән артык портретларда һәм сыннарда үзләре күзаллаганча яки мәгърифәтчене күреп белгән кешеләр тасвирыннан чыгып мәңгеләштерәләр (тулырак кара: *Портретлар һәм бюстлар*).

Р.В.Шәйдуллин, Г.И.Каюмова, Ф.Р.Бәдретдинова

А

АБДУ́ЛЛИН Искәндәр Габдулла улы (22.10.1935, Татарстанның Казан районы Олы Күлбаш авылы – 23.10.1992, Казан), тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1990).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1956), 1959 елга кадәр Чиләбе өлкәсендә укытучы булып эшли. 1962 елдан — СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында. Әрмән графикасындагы кыпчак язма истәлекләрен тикшерә, революциягә кадәрге татар публицистикасы телен өйрәнә. Өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (1977–1981), бер томлы «Татарча-русча сүзлек»не (1988) төзүчеләрнең берсе. Хезмәтләре әдәби тел тарихына һәм стилистикасына, матур әдәбият теленә, лексикологиягә һәм терминологиягә, язма ядкәрләр теле һәм текстологиягә, эпиграфикага, татар теленең башка телләр белән багланышы, шәҗәрә-генеология мәсьәләләренә, драма әсәрләренең теленә, татар телен һәм тел галимнәрен пропагандалауга карый.

Галим үзенең хезмәтләрендә күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның 1895–1896 елларда басылган, ике кисәктән торган «Ләһҗәи татари» сүзлеген («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге») үзенең хезмәтләрендә файдалана. «Татар әдәби теле үсешендә Каюм Насыйриның демократияләштерү роле» мәкаләсендә ул Каюм Насыйриның татар әдәби телен үстерүгә керткән роле турында яза. Анда К.Насыйриның 19 йөз ахырына кадәр яшәп килгән, иске үзбәк (чагатай) һәм госманлы-төрек телләрендәге формалар өстәлгән иске татар язма теленә («төрки»гә) карата мөнәсәбәтендә татар әдәби телен демократияләштерүгә китергән сәбәпләр һәм алшартлар яктыртыла. Галимнең татар телен ике вариантта — «китап» һәм «сөйләм» вариантларында каравына, соңгысы аралашуда «чистарак» һәм «гадирәк» рәвештә кулланыла дип исәпләвенә игътибар юнәлтелә. К.Насыйриның татар әдәби теле үсешен демократияләштерүдәге төп өлеше аның язма телне һәм сөйләм телен үзара якынайтуга, шул рәвешле телне һәм стильне барлык архаик һәм читтән кергән сүзләрдән арындыруга башлангыч бирүеннән, шулай ук беренче тапкыр теоретик яктан милли әдәби телнең бердәм фонетик-морфологик, орфографик, лексик-семантик, стилистик нормаларын эшләвеннән һәм өлешчә аларны кулланылышка кертүеннән гыйбарәт дигән нәтиҗә ясый.

Хезм.: Г.Камал драмаларының теле. Казан, 1968; Роль Каюма Насыри в демократизации и развитии татарского литературного языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри: Сб. к 150-летию со дня рождения. Казань, 1976.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АБДУ́ЛЛИН Яхъя Габдулла улы (09.01.1920, Татарстанның хәзерге Саба районы Зур Кибәче авылы – 04.01.2006, Казан), күренекле татар галиме, философия фәннәре доктоpы (1979), профессор (1982), ТР Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы (1996). ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1980, 1985), Бөек Ватан сугышында катнаша.

1945–1959 елларда КПССның район, аннары Казан шәһәр комитеты секретаре вазифасын башкара, район һәм шәһәр советына депутат итеп сайлана. Шул ук вакытта Казан юридик институтында һәм Иҗтимагый фәннәр академиясе (Мәскәү) аспирантурасында белем ала. 1959 елдан Казан ветеринария институтында философия укыта. 1971–1996 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында бүлек мөдире, директор урынбасары, директор; 1982–1986 елларда өлкән фәнни хезмәткәр вазифаларын башкара. 1997–2001 елларда — ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр.

Хезмәтләре татар фәлсәфи һәм иҗтимагый фикере тарихына карый, аларда мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек мәсьәләләре, күренекле татар мәдәнияте эшлеклеләренең дөньяга карашлары яктыртыла. Каюм Насыйри турындагы мәкаләләр авторы. Аларда бөек мәгърифәтченең татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырганлыгы, аның фәлсәфи-сәяси, гыйльми-педагогик, әдәби-эстетик һәм мораль-этик мәсьәләләр белән дә якыннан кызыксынганлыгы хакында яза. Шуларның һәркайсы буенча тирән фикерле әсәрләр иҗат итүен искәртә, бай һәм күпкырлы иҗат мирасындагы «Тәрбия китабы», «Әхлак рисаләсе», «Әхлак рисаләсе вә һәм фөруз мөгътәкадәт рисаләсе» кебек хезмәтләренең турыдан-туры әдәп, әхлак мәсьәләләренә багышланганын ассызыклый. «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» һәм «Кырык бакча» китапларында шулай ук әхлак мәсьәләләренең үзәк урынны биләвен ассызыклый. Әхлак һәм этика мәсьәләләренә карашларында К.Насыйриның, Көнбатыш, шулай ук рус мәгърифәтчелеге вәкилләре кебек үк, әхлакның реаль нигезләрен эзләгәндә кешенең табигатенә мөрәҗәгать итүен, аның табигый мәнфәгатьләрен яклап чыгуын һәм этик карашларын гуманизм идеяләре белән сугаруын раслый. Шуның белән бергә К.Насыйри этикасына җитди аермалар да хас булуын билгеләп үтә. Көнбатыш мәгърифәтчеләре, үзләренең этик карашларын нигезләгәндә, кеше эшчәнлегенең төп мотивларын ачуга басым ясыйлар. К.Насыйри исә игътибар үзәгенә мотивларны түгел, ә инсанның әхлакый йөзе мәсьәләсен куя, аның тәртибе ничек булырга тиешлеген, әхлак таләпләренең эчтәлеген җентекләп тикшерә, ул этиканың башка мәсьәләләрендәге кебек үк, гуманизм идеяләренә таяна. Гуманизм позицияләреннән торып, шул чор җәмгыятенә хас булган алдашу, икейөзлелек, монафикъълык, хыянәт, көнләшү, мин-минлек, үчлелек, рәхимсезлек, тупаслык, ялагайлык, ялкаулык кебек әхлакый бозыклыкларны тәнкыйть итә. Намуссыз һәм вөждансыз, шәхси мәнфәгатьләреннән башка берни турында уйламый торган, үз дигәненә ире-



Я.Г.Абдуллин

шү өчен теләсә нинди явызлыкка сәләтле бәндәләр мәгърифәтченең ачуын чыгара һәм аңарда нәфрәт хисе уята. Ул фикер хөрлеге кысылган һәм полиция күзәтүләре көчәйгән шартларда киң таралган әләкне, яла ягуны һәм гайбәтне рәхимсез фаш итә; мондый тискәре гамәлләр кешелек җәмгыятенә төзәтеп булмаслык зыян китерәләр, дип саный. Аның этикасы гаделсезлеккә һәм изүгә кискен протест белдерүе, власть ияләренең башбаштаклыгын, изүне, икейөзлекне, ялганны, мин-минлекне, исрафчылыкны, ерткычлыкны, көнчелек һәм эгоизмны рәхимсез хөкем итүе белән аерылып тора. Мәгърифәтченең этик карашлары, асылда, урта гасырчылык мөнәсәбәтләрен, шулай ук изүче катлаулар арасында киң таралган бозыклыкларны мораль яктан акларга тырышуга каршы юнәлдерелгән була һәм социаль гаделсезлеккә, явызлыкка каршы протест авазы булып яңгырый. Галимнең К.Насыйригa багышланган хезмәтләрендә шушы мәсьәләләр киң яктыртыла.

1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри иҗатында мораль-этика мәсьәләләре // Казан утлары. 1975. №2; Каюм Насыйри мирасында шәхес тәрбияләү мәсьәләләре // Совет мәктәбе. 1975. №1; Күренекле мәгърифәтчебез // Казан утлары. 1985. №4; Мәгърифәт нуры ачар... (Татар иҗтимагый фикере тарихыннан сәхифәләр). Казан, 1987; Выдающийся просветитель-гуманист // Вопросы философии. 1975. №4 (автордаш); Каюм Насыри — основоположник татарского национального литературного языка // Советская тюркология. 1975. №3 (автордаш); Татарская просветительская мысль. Казань, 1975; Общественная и философская мысль в Татарии начала XX в. М., 1990 (автордаш); Джадидизм среди татар: Возникновение, развитие и историческое место. Казань, 1998.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АДЫ́ЛОВ (Гаделев) Нәүфәл Исмәгыйль улы (04.12.1932, Казан – 01.12.2004, шунда ук), сынчы, Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1983), ТРның халык рәссамы (1993), ТР Мәдәният министрлыгының Бакый Урманче исемендәге бүләге лауреаты (2003).


Казан сәнгать училищесында С.С.*Ахун* җитәкчелегендә укый (1947–1951), Пенза сәнгать училищесының скульптура бүлеген А.А.Фомин җитәкчелегендә тәмамлый (1957). 1957 елдан СССР Сәнгать фондының Татарстан сәнгать-җитештерү комбинатында эшли. Скульптур портрет, сюжетлы, анималистик һәм монументаль-гамәли скульптура жанрларында бронза, мәрмәр, чуен һәм гипс кебек материаллар белән эшли. Агачтан композицияләр ую остасы: агачның текстур сыйфатлары һәм төс үзенчәлекләрен исәпкә алып, аны эшкәртү һәм буяуның төрле алымнарын кулланып тудырылган, фактуралар байлыгы белән аерылып торган зәвыклы пластик әсәрләр авторы. Аеруча танылган «Советлар Союзы Герое патриот-шагыйрь Муса Җәлил» (мәрмәр, 1963), «Габдулла Тукай» (гипс, 1967), «Математик Якушев» (агач, 1969), «Актёр Габдулла Шамуков» (гипс, 1960 еллар) әсәрләрендә сынчы романтизм һәм фәлсәфи уйланулар аша үз героеның эмоциональ табигатен күрсәтеп бирү дәрәҗәсенә ирешә.

Хезмәтләрендә хисләр байлыгы, декоратив сәнгать, гомумиләштерелгән образлар халык иҗаты традицияләре белән үрелеп бирелә. Әсәрләреннән берсе — «Батыр» (агач, 1967) — Советлар Союзы Герое Газинур Гафия-

туллин образын гәүдәләндерә. Рәссам тарихи жанрга («Пугачёв», агач, 1966; «Үткәннәрдән», агач, 1967) мөрәҗәгать итә. Аллегорик фигуралардан торган «Кояш чыгышы», «Яшьлек», «Картлык», «Ана» (агач, 1972), «Ромашка» (агач, 1979) скульптур композицияләрендә нечкә зәвыклы, лирик хисләр белән өртелгән хатын-кыз образларын тудыра. Гипстан һәм агачтан вак формалы әсәрләр иҗат итә («Үрдәкләр очышта», «Кыш», «Сакчылар», 1980 еллар). Шулай ук монументаль-гамәли һәм мемориаль скульптура үсешенә дә үз өлешен кертә. Ул Юдино посёлогында Граждannар сугышы герое Ян Юдин каберендәге һәйкәл-таш (мәрмәр, гранит, 1964), Җәлил посёлогындагы Муса Җәлил һәйкәле (чуен, 1967), элекке Казан сәнгать мәктәбе бинасына Н.И.Фешин һәм Б.И.Урманче истәлегенә куелган мемориаль такталар (1952) авторы. Яңа Бистә зиратының төп капкасы янындагы «Сагыш» монументы — шулай ук рәссамның күпсанлы эшләреннән берсе.



Н.И.Адылов



Н.И.Адылов. Каюм Насыйри. Агач. 1988.

2024 елның 10 февраль–17 мартында ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенең «Хәзинә» милли сәнгать галереясында Н.Адыловның күргәзмәсе уздырыла. Күргәзмәдә сынчының югары профессиональ осталык белән башкарылган эшләре, шул исәптән агачтан уеп ясалган Каюм Насыйри сыны да тәкъдим ителә. Бөек мәгърифәтче образын гәүдәләндергән тагын бер скульптур портреты — Каюм Насыйриның гипстан эшләнгән бюсты 1997 елда мәгърифәтченең туган җирендә Яшел Үзән районының Кече Шырдан авылында куела.

Төбәкара («Зур Идел», 1964 елдан), бөтенроссия («Советская Россия», 1967 елдан) күргәзмәләрендә катнаша. Бөек Октябрьнең 50 еллыгы уңаеннан Мәскәүдә узган «Советская Россия» күргәзмәсендә катнашкан бердәнбер татар скульпторы. Шәхси күргәзмәләре Казанда 1966 елда (Т.А.Зуева һәм Е.В.Зуев белән берлектә), 1982 елда (В.К.Фёдоров белән берлектә) уза, 1998 елда үзенең аерым күргәзмәсе оештырыла.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында саклана.

Әд.: Художники народов СССР: Биобиблиографический словарь. М., 1970. Т. 1; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. Казань, 1984.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

АЙТОВ Мөхәммәтҗан Сөләйман улы (05.10.1823, Казан – 1890, шунда ук), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, төбәк тарихын өйрәнүче һәм борынгы акча үрнәкләрен туплаучы. Йомышлы татарлар нәселеннән. Күренекле татар сәүдәгәре С.М.*Аитовның* этисе.

Сәүдә эшчәнлегеннән тыш татар тарихы белән дә кызыксына, Казан ханлыгының сәяси тарихын өйрәнә. Татарлардан беренче буларак, Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге Крестьяннар кузгалышына (1773–1775 еллар) бәй-

ле вакыйгаларны тасвирлап калдыра. Аның Аксак Каратун (Лука Конашевич), Е.И.Пугачёв, Ишбулат мулла, Касыйм шәехкә багышланган язмалары, ике кулъязма тарихи әсәрләр җыентыгы буларак, Каюм Насыйри тарафыннан басмага әзерләнә, ләкин ачыкланмаган төрле сәбәпләр аркасында басылмыйча кала. Безнең көннәргә кадәр сакланмасалар да, Ризаэтдин Фәхретдин һәм Оренбург өлкәсе Котлымбәт авылы кешесе Хәйретдин Исхаков хәбәрләренә караганда, әлеге кулъязма җыентыклар кулдан-кулга йөри, аларның аерым урыннары күчерелеп алына. Язмаларның бер өлеше 1926 елда «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре» җыентыгында дөнья күрә.



С.М.Аитов (уңнан беренче) гаиләсе белән. 1900 еллар.

С.Х.*Алишев* фикеренчә, шәхес, тарихчы буларак, М.Аитов Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин һ.б. тарафыннан тирән хөрмәт ителгән. Ш.Мәрҗани аның белән еш кына очрашып, тарихның төрле мәсьәләләре буенча әңгәмәләр корган. К.Насыйри үзе дә аларга еш мөрәҗәгать иткән һәм шул хакта горурланып язган.

Әд.: Алишев С.Х. Каюм Насыри и Мухаметзян Аитов // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; шул ук. По следам минувшего. Казань, 1986.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АЙТОВ Сөләйман Мөхәммәтҗан улы (01.02.1862, Казан – 1922), Казан сәүдәгәре, эшмәкәре һәм җәмәгать эшлеклесе; Каюм Насыйри турында хатирәләр авторы. М.С.*Аитовның* улы.

1897 елдан Казан шәһәр думасы гласные. Бер үк вакытта Казан сәүдәгәрләр банкы һәм Казан губернасы ятим балалар йортлары иганәчеләре идарәләре әгъзасы. 1898 елдан Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы. Исхак Арсланов вафатыннан соң 1901 елда сәүдәгәр Х.В.Гыйззәтуллин белән бергә «Арслановның сабын һәм гөлсирин җитештерү заводы ширкәте»нә хуҗа булып кала. Завод 1917 елга кадәр уңышлы эшли.

20 йөз башында татарларның милли хәрәкәтендә актив катнаша, «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең Казан бюросы эшчәнлегенә матди ярдәм күрсәтә. 1898 елда Бишбалта бистәсе мәчете төзелешенә һәм Казанда Беренче татар кыз балалар гимназиясен (Аитова Фатиха гимназиясе) оештыру һәм тотуга, Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятенә акчалата булыша. Гимназия өчен махсус кирпеч бина төзетеп, аны барлык кирәкле әйберләр белән тәэмин итә.

1896 елда Казан университеты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең* хакыйкый әгъзасы булып сайлана; татар халкының тарихи-археологик һәм әдәби истәлекләрен өйрәнә һәм туплый. Каюм Насыйри турында «Шура» журналында

мәкалә бастыра, әлеге истәлектә аның белән якыннан аралашуы, аны өенә чакырып китерүе һәм бушлай яшәтүе, балаларын укыттыруы һәм үзенең дә аңардан белем алуы, гомумән, әлеге шәхестән күп нәрсәгә өйрәнүе хакында яза.

«Беренче гомуми халык санын алудагы хезмәтләре өчен» бронза медале (1897), Станислав (1898), Анна (1904), Владимир (1908), Александр тасмаларында «Тырышлык өчен» (1916) алтын медальләре белән бүләкләнә.

Әд.: Алишев С.Х. По следам минувшего. Казань, 1986; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. Казань, 1998.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АКӘЕВ Әбусуфьян (Әбусупьян) Акай-Кади улы (1872, Дагстан өлкәсенең Тимерхан-шура округы (хәзер Дагстан Республикасының Буйнак районы) Түбән Казаныш авылы – 1931, Коми АССРның Котлас шәһәре), кумык мәгърифәтчесе, философ, илаһият галиме, җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь, нашир.

Түбән Казаныш авылы мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Тарки, Түбән Дженгутай, Темир-Хан-Шура, Сугъурале ислам уку йортларында белем ала. Гарәп грамматикасын, мөселман хокукын, хәдисләрне, риториканы, логиканы, философияне, математиканы һәм башка дөньяви, дини фәннәрне өйрәнә.

Югары белемле, шул исәптән татар һәм рус телләрен яхшы белгән шәхес буларак, тарих, әдәбият, медицина, табигыять фәннәре, педагогика белән шөгыльләнә. Төньяк Кавказ төбәгендәге мәдрәсәләрдә, беренчеләрдән булып, җәдитчә укытуны оештыра башлый. 1903 елда мәгърифәтче Магомед-Мирза Мавраев (1878–1964) белән Темир-Хан-Шура (хәзер — Буйнак) шәһәрендә гарәп хәрефләрендә нәшер итә торган «Матбагаи әл-исламийа» ташбасмаханәсен ача. Казан шәһәрендә, шул заманның атаклы Каргалы бистәсендә (Оренбург губернасы) булып, галим-голамә белән аралаша, тәҗрибә туплый. Аның әхлак темасына язылган «Аджам шиъруланы мажмасы» («Халык әсәрләре мәҗмугасы», 1912), мөселман хокукы буенча «Фазлакат әл-фараид» («Нәселдәнлек хокукы турында кыскача бәян», 1912), «Къылыкъ китап» («Әхлак китабы», 1914), медицинага караган «Гъазыр дарман» («Әзер дару», 1910, 1914), «Ильми хисап» («Арифметика», 1904), «Жаграфия» («География»), «Юз йылыкъ тынч рузнама ва малумат хасан» («Йөз елга календарь һәм кызыклы мәгълүмат») һ.б. хезмәтләрендә Каюм Насыйри шәхесе һәм эшчәнлегенең йогынтысы ачык чагылыш таба. Барлыгы 50 дән артык басма китабы билгеле. Ул — Дагстанда беренче демократик әдәби-нәфис «Танг Чолпан» («Таң чулпаны») журналын оештыручыларның берсе, авар телендәге «ХІалтІулел чагІи» («Эшче халык») газетасы һәм «Байан ал-хакаик» («Хакыйкатьне бәян итү») (1925–1928) журналының мөхәррире була.

Совет хакимиятен зур өметләр баглап кабул итә. Шуңа күрә каршы көчләр тарафыннан 1918 елда кулга алына. Озакламый большевиклар тарафыннан үткәрелгән сәясәт белән фикер аерымлыклары арта барып, 1924 елда дин әһелләре белән берлектә «Дини комитет» төзүдә актив катнаша. 1925 елдан — «Баянул хакаик» («Хакыйкать бәяны») журналының мөхәррире. 1929 елда кулга алына һәм, 10 елга сөргенгә хөкем ителеп, Котлас лагерена озатыла. Шунда вафат була. 1960 елның 15 ап-

релендә аклана. Шулай ук кара: С.Х.*Акбиев*.

Әд.: Каргалы дарелмөгаллимине (Ун еллык хатирә) // Вакыт. 1909. 18 июнь; Абусуфьян Акаев: Эпоха, жизнь, деятельность: Сборник статей, переводов и материалов. Махачкала, 2012; Акбиев С.Х. Связь времён и дружба литератур. Махачкала, 1985; Литературное и научное наследие Абусуфьяна Акаева: Сборник статей и материалов. Махачкала, 1992.

Р.Ф.Исламов.

АКА́ШИНА Нилә Мөхәммәт кызы (02.06.1959, Татарстанның Актаныш районы Актаныш авылы), педагог. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2015).

Удмурт университетының (Ижевск шәһәре) роман-герман телләре факультетын тәмамлаганнан соң, 1982–1983 елларда Сарапул халык мәгарифе район бүлегендә (Удмурт АССР) инспектор, 1983–1996 елларда Казанның 77, 388 нче балалар бакчаларында тәрбияче булып эшли. 1996 елдан — Казан шәһәре Яңа Савин районының инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, бер үк вакытта милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары.

Хезмәтләре татар телен Татарстанда туган тел һәм дәүләт теле буларак өйрәнү мәсьәләләренә карый. Ул, Татарстан халыклары милли мәдәниятләре традицияләренә, яңа уку-укыту методик комплексларына һәм заманча педагогик технологияләргә таянып, белем һәм тәрбия бирүдә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләүдә югары нәтиҗәләргә ирешә.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә куйган тырыш хезмәте өчен «Мәгарифтәге казанышлары



Н.М.Акашина

өчен» күкрәк билгесе (2010), ТР һәм РФ Мәгариф һәм фән министрлыкларының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Әд.: Призвание, ставшее судьбой: Педагогические династии Республики Татарстан — Баларга багышланган гомер: Татарстан Республикасының педагоглар династияләре. Казань, 2010.

Ф.Г.Камальтдинова.

АКБИ́ЕВ Солтанморад Хаҗак улы (18.07.1938, Дагстан АССРның Хәсәүйорт районы Боташйорт авылы – 18.01.2004, Махачкала шәһәре), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1989), профессор (1990). Дагстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1994).

1967 елда Дагстан педагогия институтын тәмамлый, 1982 елдан шунда ук укыта.

Хезмәтләре кумыкларның гарәп хәрефле язма әдәбияты тарихына, Россия халыкларының әдәби багланышларына карый. Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил иҗатына багышланган мәкаләләр авторы. К.Насыйри иҗатын тирәнтен өйрәнә. «Каюм Насыйри һәм Әбусуфьян Акаев» дип аталган язмасында татар һәм кумык халыкларының мәдәниятләрен үстерү юлында хезмәтләр калдырган мәгърифәтче-галимнәр даирәсенең иң күренекле вәкилләре — К.Насыйри һәм Ә.*Акаевның* иҗат эшчәнлекләрендәге охшашлык билгеләрен күрсәтеп, ике тугандаш халык арасындагы күпьяклы мәдәни-тарихи бәйләнешләр аспектын ачу максаты куела. Фәнни әдә-

биятны, бай архив материалларын җентекләп өйрәнү нигезендә язылган әлеге мәкалә шул елларда Шәрекъне өйрәнүгә зур өлеш керткән Казан университетының ролен шактый киң һәм тулы итеп күрсәтү ягыннан да аерым әһәмияткә ия. Әлеге басмада татар һәм кумык халыкларын агартуга гомерләрен багышлаган мәгърифәтче әдипләрнең фәнни эшчәнлекләре җентекле тикшерелә, алар арасындагы бәйләнешләр тулы тасвирлана. Автор аерым мисаллар нигезендә Акаевның бөек татар галиме К.Насыйрига якын булуын, аннан күп нәрсәгә өйрәнүен раслый. Аның эстетик карашлары кумык әдәбиятының күренекле вәкилләре Дәүләт-Мирза Шихалиев, Магомед-Нури Османов, Темирбулат Бейбулатов, Нухай Батырморзаев һ.б.га да уңай йогынты ясавын ассызыклый. К.Насыйри һәм Ә.Акаевның бер үк үрнәктә диярлек матбугат органнары оештыру эшчәнлекләре дә игътибарга лаек. Насыйри «Таң йолдызы» газетасын чыгарырга әзерлек алып барган булса, Акаев Дагстанда «Таңг Чолпан» исемле демократик юнәлештәге беренче әдәби журнал оештыруда актив катнаша һәм аның битләрендә үзенең мәкаләләрен, халык иҗаты әсәрләрен бастыра. Шул рәвешчә, әдәбият, педагогика, тарих, медицина, табигыять белемнәре һәм башка өлкәләрдә татар мәгърифәтчесе башкарган хезмәтләр аның кече замандашы Акаев эшчәнлегендә дәвам ителә һәм үстерелә.

Хезм.: Каюм Насыйри һәм Әбусуфьян Акаев // Казан утлары. 1975. № 2; Тукай турында... // Дөнья халыклары Тукай турында. Казан, 2006; Каюм Насыри и Абусуфьян Акаев (к вопросу типологического единства их творчества) // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Некоторые вопросы развития межнациональных связей дагестанской литературы. Махачкала, 1989.

Әд.: Исламов Ф. Әдәбиятлар дуслыгын яктыртучы хезмәт // Казан утлары. 1988. № 5.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АКЧУ́РИН Алимҗан (Галимҗан) Кәлимулла улы (1895, Пенза губернасының Краснослободск өязе Югары Рахман авылы – 1933, Мәскәү), сәясәт эшлеклесе, шагыйрь, шәрекъ телләре белгече, тәрҗемәче.

Казан өязендәге Кышкар мәдрәсәсен тәмамлый (1907), 1910–1912 елларда «Касыймия» мәдрәсәсендә укый, шәкертләр хәрәкәтендә катнаша. 1914–1915 елларда Төркестанда мамык чистарту заводында эшли. Беренче бөтендөнья сугышы елларында, 1915 елда, Россия армиясе сафларына алына; 1917–1920 елларда Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. 1917–1918 елларда — Чаржоу шәһәрендәге Бохара революцион трибуналы әгъзасы, 1918–1919 елларда — Төркестан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Төркестан АССР Тышкы эшләр комиссариатының баш коллегиясе әгъзасы. 1920–1926 елларда — Харәзем, Бохара Халык Совет Республикаларында коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты 1 нче секретаре. 1926–1928 елларда — ТАССР финанс халык комиссары урынбасары. 1930 елдан — Ташкент ВКП(б) тарихы фәнни-тикшеренү институты гыйльми хезмәткәре.

Казанда яшәгән вакытта иҗат итә башлый, 1913–1916 елларда лирик шигырьләре «Сөембикә», «Шура» журналларында, «Йолдыз» газетасында басыла. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов әсәрләрен тәрҗемә итә. Шулай ук Каюм Насыйри турында истәлек язучы буларак та билгеле. Аның «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында

кайбер мәгълүмат» мәкаләсе беренче тапкыр 1912 елда «Шура» журналында дөнья күрә. Анда татар, башкорт һәм казакъ мәктәпләре буенча Казан уку-укыту округы инспекторы В.В.*Радлов* тәкъдиме белән 1871 елда Казанда татар балалары өчен башлангыч рус-татар мәктәбе ачылу турында бәян ителә. В.В.Радлов 3 мөселманны үзенә мөгаллимлеккә чакыра. Берсе — китаплар, сүзлекләр авторы Каюм Насыйри, икенчесе — педагог, мәктәп мөдире Шаһбазгәрәй Әхмәров һәм өченчесе педагог, табигыять фәннәре белгече, ветеринария табибы, «Шәрекъ клубы»н оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе — Ибраһим Терегулов була.

Бохара Халык Совет Республикасының алтын һәм көмеш Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат // Шура. 1912. №23; Воспоминания о двадцатом годе в Хиве и Бухаре // Сборник статей к десятилетию бухарской и хорезмской революции. Ташкент, 1930.

Әд.: Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Псевдонимы в татарской литературе. Казан, 2021; Шарафутдинов Д. Акчурин А.К. // Борцы за счастье народное. Казань, 1988. Кн. 3.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АЛИ́ШЕВ Сәләм Хатип улы (20.03.1929, Татарстанның Чистай кантоны Шәрбән авылы – 24.06.2015, Казан), тарихчы, тарих фәннәре докторы (1990), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1996), Каюм Насыйри иҗатын фәнни җирлектә өйрәнүче.

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, 1951–1960 елларда Лаеш районы Татар Сараланы авылы мәктәбендә укыта, уку-укыту бүлеге мөдире, директор булып эшли. 1960–1962 елларда — Югары Ослан районында мәгариф бүлеге мөдире. 1966 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1990–1996 елларда — тарих бүлеге мөдире. 1997 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр.



С.Х.Алишев

Хезмәтләре татар халкы, Урта Идел буе, Казан ханлыгы һәм аның Рус дәүләте белән үзара мөнәсәбәтләре тарихына һәм тарихи чыганакларына, Урта Идел буе халыкларының Россиягә кушылганнан соң барлыкка килгән социаль-икътисади халәтенә, татар халкының милли-сәяси изүгә каршы көрәшен өйрәнүгә карый. К.Насыйри әсәрләренең ике томлыгын (1974–1975) төзи һәм тарихи хезмәтләрен бастыруга әзерли. «Каюм Насыйри һәм Мөхәммәтҗан Аитов» мәкаләсендә Россия империясенең 19 йөзнең 2 нче яртысы иҗтимагый тормышында татар халкының күренекле фикер ияләре эшчәнлегенә этәргеч биргән алшартлар яссылыгында К.Насыйриның һәм М.*Аитовның* тарих фәнендәге һәм историографиядәге урыны, аларның үзара мөнәсәбәтләре яктыртыла. К.Насыйриның историографиядәге казанышлары өч юнәлештә бәяләнә: 1) татар укучысын рус халкы тарихы белән таныштыру максатында рус тарихына караган хезмәтләр нигезендә милли фикер даирәсендә беренче тапкыр «Россиянең кыскача тарихы»н язуы һәм нәшер итүе белән үз халкы арасында Рус дәүләте тарихын беренче популяр-

лаштыручы булуы; 2) тарих, археология һәм этнография буенча фактик материаллар, аеруча фольклор әсәрләре җыю һәм туплавы нәтиҗәсендә фәннең тикшеренү җирлеген һәм өлкәләрен баетуы; 3) мәгърифәтче буларак, халык массалары арасында фәнни, шул исәптән тарихи белемнәр таратуы белән татарларны мәдәни агартуга, алдынгы карашлар һәм фикерләр үсешенә зур өлеш кертүе. Мәкаләдә автор тарафыннан К.Насыйриның халыкчан асылдагы иҗатын өйрәнү барышында татар историографиясенең тагын бер вәкиле аныкланы, аның безгә К.Насыйри шәхесе аша ачылуы, икесенең дә татар җәмгыятенең прогрессив көчләре вәкилләре булулары, иң беренче чиратта үз халкы мәнфәгатьләрен алга сөрүләре хакында нәтиҗә чыгарыла.

Хезм.: Кәһарман бабайлар. Казан, 1976; Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. Казань, 1973; Каюм Насыри и Мухаметзян Аитов // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI – нач. XIX вв. М., 1990; Историки. Татарский народ. Казань, 2000; Источники и историография города Казани. Казань, 2001; Казанское ханство. Казань, 2002; Всё об истории Казани. Казань, 2005.

Әд.: Салям Хатыпович Алишев. Казань, 1999.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АЛИ́ШЕВ Хатип (?–?), Каюм Насыйри турында истәлек сөйләүче. Истәлегендә мәгърифәтче галим белән 1884–1895 еллардагы әңгәмәләрен, әдипнең йорт җиһазларын, аңардан бер ай чамасы геометрия фәненнән дәресләр алуын, аның язган әсәрләрен укып файдалануын тасвирлый. К.Насыйриның төрле һөнәр һәм гыйльми мәсьәләләр турында сөйләргә яратуын әйтә һәм аны олы йолдыз дип атый. «Без дә күзләребез яхшы ачылып җитмәгән заманда, Каюм абзый Насыйри кебек, олы йолдызларны күрә алмадык. Аны кечкенәгә санадык, «Сукыр Каюм» гына дип йөрттек. Менә хәзер күзләребез ачыла төшкәч, Насыйриның зурлыгы күренә башлады. Дөрестән дә ул олы йолдыз икән...», — дип искә ала. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Хатип Алишев истәлекләре: Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Ф.С.Гыйниятуллина.

А́ЛКИН Шәйхулла Сибгатулла улы (15.08.1893, Казан губернасы Зөя өязе Иске Чәчкаб авылы – 1918 яки 1922), сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы.

1913 елда Казан Коммерция училищесын тәмамлый. 1913–1918 елларда (бүленеп) Мәскәү коммерция институтында укый. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары эшендә катнаша, көндәлек матбугатта аларның барышы турында хәбәрләр урнаштыра. Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче корылтаенда (Казан) Милли Шурага сайлана. Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтарияте нигезләрен эшләү комиссиясе эшендә катнаша. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–1918), анда финанс эшләре комиссиясе җитәкчесе була, Малия (финанс) нәзарәте рәисе итеп сайлана. Булачак Идел-Урал Штаты биләмәсенә Әстерхан һәм Самара губерналарын да кертү кирәклеген дәлилли. Төп карашы буенча милли-мәдәни мохтарият (автономия) тарафдары. 1917 елгы Октябрь революциясен кабул итми. 1918 елның көз башында,

Кызыл Армия Уралга якынлашкач, бер төркем Милли Идарә әгъзалары белән бергә, Уфаны калдырып, Себер тарафына күчеп китә. Уфадан киткәннән соңгы тормышы билгесез.

1913–1914 елларда «Ил» газетасы, «Ак юл» журналы белән хезмәттәшлек итә. Матбугатта балаларга багышланган беренче хикәяләре, русчадан тәрҗемәләре дөнья күрә. Беренчеләрдән булып, Каюм Насыйри хатларын «Аң» журналында бастыра. Әлеге хатларны ул бер авылда таба һәм, эчтәлекләре бер төрле булу сәбәпле, сигезен генә укучылар игътибарына тәкъдим итә. Әтисе Габденнасыйргa, туганнарына һәм төрле кешеләргә юлланган әлеге хатларда К.Насыйри матди кысынкылык кичерүе, «...үзенең айга унөч сум жалуниясенең җитмәгәнлеге, ашчы малай өйрәтүнең читенлеге...» турында яза.

Хезм.: Каюм Насыйри хатлары // Аң. 1912. № 1; Балалар күңеле. Казан, 1921.

Әд.: Давлетшин Т. Советский Татарстан (теория и практика ленинской национальной политики). Лондон, 1974; Султан-Галиев М. Избранные труды. Казань, 1998; Усманова Д. Шайхулла Алкин // Татарстан. 1995. № 9–10.

Ф.С.Гыйниятуллина.

АЛТМЫ́Ш ҖИДЕНЧЕ́ БАЛАЛА́Р БАКЧАСЫ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы; ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләгә лауреаты (2022).

Казан шәһәренең Совет районында урнашкан. 2011 елда, 220 урынга исәпләнеп, «Бәләкәч» программасы буенча ачыла. 2014 елда икенче бинасы төзелә. Балалар бакчасындагы барлык 15 төркемдә дә (төп бинада — 4 яшьтән 7 яшькәчә 11 төркем, икенче бинада — 3 яшьтән 5 яшькәчә 4 төркем) тәрбия һәм укыту-өйрәтү эшләре татар телендә алып барыла.

Эшчәнлегендә балаларны Татарстан Республикасы халыклары милли мәдәниятләре традицияләренә нигезләнеп, музей педагогикасын файдаланып тәрбияләүгә юнәлеш тота. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләмен үстерү проектларын сынау буенча федераль инновацияләр кертү һәм шәһәр, район күләмендә инновацияләр куллану мәйданчыклары булып тора. Музыка һәм физик үсеш дәресләре катгый рәвештә дәресләр тәртибендә этномәдәни төбәк компонентын кулланып уздырыла. ТР Милли музее, «Салават күпере» журналы, «Мирас» татар теленә өйрәтү район методик берләшмәсе, «Ак калфак» халыкара татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Казан бүлекчәсе белән хезмәттәшлек итә.

Балалар бакчасы «Уен мәйданчыгы — сәламәтләндерү, тәрбия, үсеш территориясе» (2019), «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» (2020), Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, традицияләрен, мәдәниятләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән «Мирас угы» («Стрела наследия») (2021) грантлары иясе.

И.Х.Хәлиуллин.

АНАТО́МИЯ (грек теленнән anatomé — аеру, кисү, яру), кара: *Медицина*.

АРИФМЕ́ТИКА (борынгы грек теленнән arithmetika, arithmys — сан), саннарның иң гади үзлекләрен һәм алар өстендә эшләнә торган гамәлләрне (кушу, алу, тапкырлау, бүлү һәм исәпләүләрдә кулланыла торган алымнар) өйрәнү белән шөгыльләнүче математика бүлеге.

Арифметика Борынгы Көнчыгыш илләрендә барлыкка килә һәм үсеш ала: борынгы Мисырда урта патшалык чорына (безнең эрага кадәр 21–18 йөзләр тирәсе) караган папируслардагы язмаларда гамәли характердагы арифметик мәсьәләләр булган. Россиядә «арифметика» атамасы Л.Ф.Магницкийның «Арифметика» (1703) беренче рус басма дәреслеге чыккач кулланыла башлый.

Татарларның математика гыйлеме тарихы Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына барып тоташа. Математика белемнәренең киң таралуына гарәп трактатлары ярдәм итә, шул хезмәтләрдән мәдрәсә һәм мәктәпләрдә гамәли арифметиканы укыту өчен күчермәләр ясыйлар, кайбер галимнәр исә аларга шәрехләмәләр язалар яки шуларга охшатып яңаларын төзиләр. Мәсәлән, Алтын Урдада математика темасына язылган «Әт-төхфә фи гыйлем әл-хисаб» («Хисаплау фәнендә бүләк», 13 йөзнең 1 нче яртысы) исемле әсәр мәгълүматларының камиллеге буенча аерым урын алып тора. Бу яктан 16–19 йөзләрдәге математик эчтәлекле татар кулъязма чыганаклары зур әһәмияткә ия, һәм аларда билгеле бер математик мәгълүматлар даирәсе (сүз, язма нумерация (алфавит һәм унарлы саннар), бөтен саннар арифметикасы, вакланма саннар арифметикасы, билгесезләрне табу кагыйдәләре, геометрик фигураларның мәйданнарын үлчәү) бар. 19 йөзнең 2 нче яртысында татар мәгариф системасында җәдитчелек ысулы таралу белән, мөселман дини уку йортларында арифметикага караган кулъязма китаплар урынына әкренләп басма уку әсбаплары кулланыла башлый. Шундый хезмәтләрнең берсе — Каюм Насыйриның 1873 елда Казан рус-татар мәктәбендә эшләгәндә басылган «Хисаплык, ягъни гыйльме хисап кагыйдәләре яки арифметика вә хисаплык мәсьәләләре» китабы.

К.Насыйри, өйрәнү материалын тормыш белән якынайту, предметларның үзара бәйләнеше һәм укучыларда актив математик фикерләү тәрбияләү бурычларын куеп, табигыять-математика фәннәрен укытуда яңалык кертә. Ул төзегән арифметика фәнни характерда була һәм ике мәдәниятнең — Көнчыгыш һәм Европа илләренең математика өлкәсендәге казанышларының иҗади синтезын тәшкил итә. Үзенең дәреслекләрендә галим 19 йөзнең 2 нче яртысындагы рус педагогларының методик идеяләрен киң куллана, аерым алганда, арифметика дәреслеге кулъязмасының кереш сүзендә күренекле рус педагогы И.И.Паульсонның «Сыйныфта эшләү өчен арифметикадан мәсьәләләр һәм язма күнегүләр җыентыгы» («Арифметический задачник для письменных упражнений в классе») исемле уку әсбабын телгә ала. Ул да, Паульсон кебек, укытуның аналитик аваз ысулы һәм арифметиканы аңлатмалы укыту тарафдары була.

К.Насыйри дәреслекләре эчтәлек, төзү системасы һәм укыту ысуллары ягыннан татар мәктәпләре укучылары өчен гади һәм аңлаешлы телдә язылган. Арифметиканы гамәлдә куллануның кайбер өлкәләрен яктырткан мисаллар һәм мәсьәләләр тормыштан алынган. Шул ук вакытта аның уку әсбабында «Ике көтүче», «Кәҗә, бүре, кәбестә», «Өч сәүдәгәр» кебек зиһен сынашмак үрнәгендә төрле табышмак-мәсьәләләр дә бирелә. Дәреслекләрдә хәбәр ителә торган арифметик мәгълүматлар киң колачлы булуга карамастан, аларның төп максаты һәм юнәлеше укучыларны кайбер беренчел арифметик төшенчәләр һәм фактлар белән таныштырудан һәм хәбәр

ителә торган мәгълүматларны алга таба гамәли мәсьәләләрне чишкәндә кулланырга өйрәтүдән гыйбарәт. Аның укыту системасы нигезендә уку-укыту материалын билгеле бер тәртиптә һәм эзлеклелек белән бәян итү, күрсәтмә әсбаплар куллану һәм укыту процессын гамәли тормыш белән якынайту омтылышы, укучыларда мөстәкыйльлек, кызыксынучанлык һәм дәрестә активлыкны үстерергә ярдәм итә торган күнекмәләр булдыру принциплары ята.



К.Насыйри.
«Хисаплык» хезмәтеннән бер бит. 1899.

Арифметика буенча беренче дәреслекләр төзегәндә бер үк вакытта татар телендә фәнни терминология эшләве К.Насыйриның зур казанышы булып тора. Ул һәр математик төшенчәгә зур игътибар бирә. Аның арифметикага керткән күп кенә сүзләре татар әдәби теленә ныклап кереп киткән һәм хәзер дә математика буенча мәктәп дәреслекләрендә үзгәрешсез кулланыла (мәсәлән, сан, кушу, алу, тапкырлау, бүлү). Арифметика буенча беренче дәреслекләре белән галим татар яшьләренә дөньяви белемнәргә киң юл ачып кына калмый, ә математика буенча дәреслекләрне алга таба фәнни эшкәртү өчен ныклы нигез дә булдыра.

К.Насыйри дәреслекләренә үз вакытында күренекле рус галимнәре Н.Ф.Катанов һәм Н.К.Дмитриев тарафыннан югары бәя бирелә. Мәсәлән, «*Хисаплык*» китабының 1899 елда тулыландырып нәшер ителгән икенче басмасындагы уңай якларга игътибарны юнәлтеп, Н.Ф.Катанов: «Элекке гарәп телендә булмыйча, яңача Европа ысулында язылган, бигрәк тә киң катлауга аңлаешлы телдә татарча бу китап танылган Казан галиме Габделкаюм Насыйровныкы... Терминнар барысы да бик уңышлы сайланып, моңа кадәр булган дәреслекләрдә аңлашылмый торган борынгы гарәпчә урынына, асыл татарча сүзләрдән төзелгән. Гомумән, Насыйровның дәреслеге татар педагогикасында игътибар ителергә тиешле гаять файдалы яңалык булып тора», — дип яза.

Чыг.: Насыйри К. Хисаплык, ягъни гыйльме хисап кагыйдәләре яки арифметика вә һәм хисаплык мәсьәләләре. Казан, 1873; шул ук. Хисаплык. Гыйлем хисап фәнендә мөстәкыйль бер китаптыр. Казан, 1899.

Әд.: Беркутов В.Г. Развитие математического образования булгаро-татар. Казань, 1997; Катанов Н.Ф. Хисаплык (числительная, или арифметика). Казань, 1899. Тип. ун-та. 85.8. // Деятель. 1900. № 6–7; Фахрутдинов Р.З., Даутова Г.Ж. Педагогическое наследие К.Насыри и совершенствование естественно-математического образования в школе // Материалы Всероссийской научно-практической конференции «Педагогическое наследие Н.М.Таланчука и современные проблемы социального воспитания». Казань, 2002; Tiesenhausen W. Altınordu Devleti Tarihine Ait

Metinler, Qev. Ismail Hakki Izmirli, Maarif Matbaası. Istanbul, 1941.

Р.В.Шәйдуллин.

АРСЛА́НОВ (Арасланов) Госман Вәли улы (1897–1941, Казан), рәссам, график, карикатура остасы, татар профессиональ китап графикасына нигез салучыларның берсе.

Пермь сәнгать остаханәсен тәмамлый (1922). 1917 елда Пермь шәһәрендә уздырылган Габдулла Тукайны искә алу кичәсендә әдипнең күргәзмәгә куелган зур форматтагы портреты авторы. 1920–1922 елларда — Пермь драма театрында бизәүче рәссам ярдәмчесе. 1922 елдан — Казанда: 1923 елда татар театры өчен К.Гоццинның «Принцесса Турандот» әсәре буенча куелган спектаклгә декорация эскизлары ясый.

«Чаян» журналы чыга башлагаННан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр әлеге басмада әйдәп баручы рәссамнарның берсе була. Аның ике-өч төс белән башкарылган гротесклы рәсемнәре «Чаян» журналы тышлыкларында басыла һәм сәяси мәкаләләрне бизи. Бер үк вакытта, 1920–1930 елларда, «Азат хатын», «Октябрь яшьләре», «Кызыл Татарстан» вакытлы матбугат басмалары белән хезмәттәшлек итә, китаплар бизи. Беренчеләрдән булып, Г.Тукайның сайланма әсәрләре җыентыгына (1926) рәсемнәр ясый; 1920–1930 елларда шагыйрьнең «Су анасы», «Шүрәле», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмалары, «Мияубикә», «Муллаларның зары», «Номерга төшкән искеләр» һәм башка шигырьләре иллюстрацияләр белән аерым китаплар булып дөнья күрә.

Рәссам тарафыннан сурәтләнгән иске Казан күренешләрендә, 20 йөз башы мөселманнары портретларында узган чорларның тарихи-этник йөзе чагылыш таба. Шулар арасында Каюм Насыйри портреты да була. Язучы Нәкый *Исәнбәт* истәлекләренә караганда, Фатих *Әмирхан* 1925 елның 15 февралендә Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулу уңаеннан ТАССР Мәгариф халык комиссариаты карамагындагы *Гыйльми үзәктә* ясаган чыгышында галимнең Г.Арсланов тарафыннан эшләнгән портретына карата мөнәсәбәтен белдереп: «Бу рәсем белән мин мотлак разый түгелмен! Бу рәсем мин күзаллаган галим Каюм Насыйригa бер дә охшамаган», — дип нәтиҗә ясый.



Г.В.Арсланов.
«Каюм Насыйри» портреты.
1920 еллар башы.

«Безнең басма» җыентыгының рәссам эшләгән тышлыгы Париждагы Халыкара бизәлеш сәнгате күргәзмәсенә (1925), сатирик рәсемнәре 1930 еллардагы Татарстан Республикасы күргәзмәләренә куела. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм ТР Милли музеенда саклана.

Әд.: Дульский П.М. Актуальная графика. Казань, 1935; шул ук. Оформление татарской книги за революционный период. Казань, 1930.

Р.В.Шәйдуллин.

АРСЛА́НОВА Рәхимә Минвәли кызы (03.03.1964, Татарстанның Лаеш районы Державино авылы), педагог, балалар шагыйрәсе, ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2019). ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Абдулла Алиш (2023) исемендәге бүләге иясе. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2014).

Алабуга педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1989), Чаллы (1983–1992), Казан (1992–1996) шәһәр мәктәпләрендә укыта. 1996 елдан Сарман районы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбендә укыта, 2001 елдан — мәктәп директоры, 2003 елдан — тәрбия эшләре буенча директор урынбасары. 2008 елдан — Казанның Совет районы буенча Шәһәр методик үзәгендә милли һәм башлангыч белем бирү методисты, 2011 елдан — шул районның Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиясе (кара: *Егерменче гимназия*) директоры. Бер үк вакытта, 2017 елдан, «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Казан бүлеге җитәкчесе. Укучыларда иҗади шәхес һәм милли үзаң тәрбияләү максатыннан аларның милли, социаль-икътисади, мәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, бөек татар мәгърифәтчеләренең хезмәтләренә таянып, гимназиядә татар телендә укыту һәм тәрбия бирү системасын камилләштерү өстендә эзлекле эш алып бара. Ул Каюм Насыйриның тәрбия тәгълиматларын үрнәк итеп ала, мәгърифәтчегә багышланган чараларда, конференцияләрдә актив катнаша. «Иске татар бистәсе» музеенда К.Насыйригә багышланган аерым экспозиция буенча укучыларга кызыклы экскурсияләр уздыра. Аның тырышлыгы белән «Алиш варислары» (2013), «Милли мирас» (2015), «Мәңгелек хәтер» (2016), «Иске Татар бистәсе» (2017) музейлары ачыла.



Р.М.Арсланова

Шигырьләре матбугат битләрендә, җыентыкларда басыла, китаплар булып чыга, 3 китабы русчага тәрҗемә ителә. Бөек рус шагыйрьләре А.С.Пушкин, Г.Р.Державин шигырьләрен тәрҗемә итә.

Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале, «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә; «Илһам-Вдохновение», «Әдәби карта», «Балачак җыры» республика әдәби бәйгеләре җиңүчесе.

Әсәр.: Табышмаклар һәм ялиттергечләр. Казан, 2006; Кыш бабай ник чирләгән? Казан, 2013; Сәяхәтче = Путешественник. Казан, 2014; Әкиятләр = Сказки. Казан, 2015; Тәмлетамак = Сладкоежка. Казан, 2018; Кунак кызы. Казан, 2019; Дүрт җайдак. Казан, 2021; Уңган булып үсәбез. Казан, 2023.

Ф.Г.Камальтдинова.

АРХЕОЛО́ГИЯ (грек теленнән archaios — борынгы һәм logos — сүз, фән), сакланып калган матди чыганаклар нигезендә кешелек дөньясы тарихын өйрәнүче фән. Аның төп принцибы — кешенең һәр эшчәнлеге эз калдыра. Матди чыганаклар — җитештерү кораллары һәм алар ярдәмендә барлыкка китерелгән матди байлыклар: корылмалар, кораллар, бизәнү әйберләре, савыт-саба, сәнгать әсәрләре һ.б., кыскасы, кешеләр тарафыннан җитештерелгән барлык әйберләр.

«Археология» термины беренче тапкыр безнең эрага кадәр 4 йөздә грек

философы Платон тарафыннан борынгы дәверләргә нисбәтле фәннәрне күздә тотып кулланыла. Фән буларак, археология Россиядә 18 йөз башында барлыкка килә. Россия патшасы Пётр I нигез салган Кунсткамерада борынгы әйберләр һәм археологик истәлекләр туплана. Археологик истәлекләр турында мәгълүматлар туплау дәүләт эшенә әверелә.

Казан төбәгендә киң планлы археологик тикшеренүләр үткәрү 19 йөзнең 2 нче ярты сыннан башлана. 1870–1890 елларда А.Ф.Лихачёв, Н.П.Лихачёв, А.А.Штукенберг, Н.Ф.Высоцкий, Ф.Д.Нефёдов, П.А.Пономарёв һ.б. Казан артында һәм Чулман аръягында бронза һәм әүвәлге тимер гасырлар истәлекләрен казу эшләре үткәрәләр. С.М.Шпилевский Казан губернасындагы борынгы истәлекләр турында гомумиләштерелгән хезмәт яза, ул анда болгар чоры истәлекләренә беренче тапкыр фәнни тасвирлама бирә. Татарстан территориясендә таш, бронза һәм тимер гасырларга караган истәлекләр табыла.

Зур әһәмияткә ия булган археологик истәлекләрне тәртипкә китерү һәм саклауга 1877 елда Казанда үткәрелгән Дүртенче археология съездында оештырылган *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* мөһим өлеш кертә. Археологик истәлекләрне комплексны тикшерүгә нигез салына.

Энциклопедист галим буларак, Каюм Насыйри берничә дистә еллар дәвамында тарих һәм археология мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Ул археологик һәм эпиграфик истәлекләрне өйрәнә, татар халкы тарихына кагылышлы хикәяләр, *риваятьләр*, *җырлар* һәм *бәетләр* җыя. Әлеге эзләнүләре һәм тикшеренүләре белән галим тарих фәнен яңа тарихи-археологик чыганаклар белән тулыландырырга омтыла. Ул: «Без рус тарихчылары әйткәнне кабатларга теләмибез. Без «Рус тарихларында» булмаган риваятьләрне җыярга омтылабыз», — дип яза. Тарихчы Хәйри *Гыймади* әйтүенчә, галимнең әлеге өлкәгә караган 10 хезмәте бар, алар башлыча җирле төбәк тарихын чагылдыра, татарларның үзе җыйган авыз иҗаты материалларына һәм археологик, эпиграфик мәгълүматларга нигезләнә. Мәсәлән, Иске һәм Яңа Казан шәһәре, Казан ханлыгы тарихы һәм археологиясе буенча гаять бай мәгълүмат туплап, алар нигезендә «Тәварихы Казан» хезмәтен яза. Ул 1926 елда «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга» җыентыгында дөнья күрә.

К.Насыйриның тарихи-археологик кулъязмалары шәркыятьче галим И.Ф.*Готвальд* (1813–1897) вафатыннан соң аның шәхси китапханәсе белән бергә Казан университеты Фәнни китапханәсенә тапшырыла. Хәзерге вакытта алар Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә* сакланa. Әлеге кулъязмаларда Казан губернасы Зөя һәм Цивильск (Чуел) өязләренең зур татар авыллары тарихы һәм халкы турында халык риваятьләре һәм аларга караган археологик һәм эпиграфик материаллар бар (кара: *Зөя өязе*). Гали *Рәхим*: «Бу хезмәтләрдә Насыйров [археологик] материалга дөрес фәнни яктан каравын, тикшергәндә сизгерлеген һәм саклык белән эшләвен күрсәтә», — дип билгеләп үтә. Ул, нигездә, Зөя һәм Цивильск өязләре татар авыллары зиратларындагы борынгы кабер ташларын (кара: *Эпиграфика*) барлый, археологик табылдыклар, шәһәрлекләр, авыллыклар һәм башка төрле тарихи истәлекләр турында җирле халык арасында таралган риваятьләрне туплый. Соңыннан аларны, *Археология, тарих*

һәм этногафия җәмгыяте әгъзасы буларак, шул оешманың галимнәре карамагына тапшыра, кайбер өлешен төрле хезмәтләрендә, шул исәптән календарьларында бастыра. Яшел Үзән районының хәзерге Тауиле авылы янында урнашкан Тауиле болгар шәһәрлеге сүзенең этимологиясен «Тау иле» («Тау ягы») дигән тарихи атама белән тиңләштерә.

Археология һәм этнография мәсьәләләре белән кызыксынучы галим буларак, К.Насыйрины ул вакытта Казанда Н.Ф.*Катанов*, В.В.*Григорьев*, В.В.*Радлов* кебек танылган шәркыятьче галимнәр югары бәяли. Аларның ярдәме белән ул тарихи-археологик эзләнүләрдә актив катнаша. Аның басылмаган кулъязмаларының бер өлешен Н.Ф.Катанов барлап һәм тәрҗемә итеп бастыра. Шул басманың кереш сүзендә ул болай дип яза: «Мәрхүм татар галиме Абдул Каюм Абдулнасыйровның 1880 елда Казанда басылган 1881 елгы календаренда Иске Казан турында рус җәмәгатьчелегенә билгеле булмаган, татарларның борынгыларны ничек хәтердә тотуын ачык күрсәтә торган күп кенә татар хикәяләре китерелә, мин алар белән рус укучыларын таныштырырга телим».

Әд.: Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926; Шәймәрданов Р.Х. Габделкаюм Насыйри ижаты һәм эшчәнлегенең бүгенге көн әһәмияте // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения Каюма Насыри. Казань, 2015; Али Рахим (Абдрахимов) Каюм Насыров (к 100-летию со дня рождения) // Вестник научного общества татароведения». 1925. № 1–2; Гимади Х.Г. О трудах Каюма Насырова в области собирания историко-археологических материалов // Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвящённых 120-летию со дня рождения). Казань, 1948; Фахрутдинов Р.Г. Вклад Каюма Насыри в исследование истории и археологии казанских татар // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Р.В.Шәйдуллин.

«АРХЕОЛО́ГИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ́ (Зөя өязе авыллары буенча)», кулъязма, Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан 1926 елда Гали Рәхим тарафыннан әзерләнгән җыентыкта бастырыла. Аңа Каюм Насыйриның Тау ягы, ягъни Зөя, Цивильск, Чабаксар өязләрендәге авылларда үзе йөреп туплаган тарихи-археологик материаллар һәм *риваятьләр* керә.

Башта К.Насыйри тарафыннан Зөя шәһәренең ничек корылуы хакында ике риваять китерелә. Аннары Әҗәл авылы турында бәян итеп, ул аның шул вакыттагы Татар Әҗәлесе һәм Рус Әҗәлесе дигән ике авыл булуын күрсәтә. Әҗәлене Болгардан килгән Хаҗ Гали исемле кеше нигезләвен белдерә. Авыл элекке урыныннан бераз икенчерәк урынга күчкән икән. К.Насыйри үзенең бертуган энесе Габделкави һәм Әҗәле мулласы белән 1469 елга караган бер кабер ташындагы язуларны укыганлыгын да искә ала. Якынча 1626 елдан башлап имам булып торган биш кешенең исемнәрен күрсәтеп, анда инде башка имам булмаганлыгын әйтә.

Хезмәттә Панау авылының килеп чыгышы, Николай исемле качкын полякка бәйләп, «әфәнде» сүзенең тәрҗемәсе — полякча «пан» сүзе белән аңлатыла.

Мамадыш-Әкил, Тәүгилде-Мамадыш (Танай), Мамадыш-Салтыган

(Ышналыбашы), Багаево-Мамадыш, Мамадыш-Арсланова, Мамадыш-Гордеево авыллары (соңгы өчесе — рус авыллары), риваятьләр буенча, Биләр шәһәреннән килгән Җәммәт исемле кешенең балалары тарафыннан нигезләгән дип күрсәтелә. Мамадышта һәм Танайда имам булып торган кешеләрнең исемнәре китерелә, Танай зиратындагы кабер ташларының 1526, 1533, 1550 елларда куелганы ачыклана.

Югары Шырдан (кара: *Кече Шырдан*) авылын нигезләүчеләр Болгардан килгән алты кешегә нисбәт ителә. К.Насыйри үзенең Габдеррәзак бабасының (этисенең этисе) чыгышы белән әнә шул кешеләрдән берсенең (исеме мәгълүм түгел) туганы булуын; ул кешенең, заманында дәүләт эшләренә катнашып, бик мул тормышта яшәвен, әмма фәкыйрьлектә үлүен; Хөсәен бабасының тормыш юлын бәян итеп, аның матур язуга осталыгын, берничә йөз данә Коръән күчереп язганлыгын күрсәтә.

Мулла Иле авылының тарихы шулай ук Болгардан килеп нигез салган Муллагыл исемле кешегә нисбәт ителә. Аның белән бергә килгән Шәехби дигән кешенең асыл чыгышы Кытайдан икән. Мулла Иленә соңрак Хуҗаш (1660 елларда), Өҗем (Мәҗин) авылларыннан да күчеп утырганнар. Авыл зиратында 1493, 1850 еллар белән билгеләнгән кабер ташлары барлыгы хәбәр ителә.

К.Насыйри язганча, Бакырчы авылы бик борынгылардан булып, элек анда мөселманлашкан мукшылар яшәгән. Ул Динмөхәммәт исемле мулланың бер китабында унике буынны эченә алган *шәҗәрәгә* тап булуын белдерә. Авылның исеме бакырчылык һөнәренә бәйләп аңлатыла. Бакырчы зиратында 1522 елларда вафат булган Мөхәммәт Чәләби хаҗи кабере бар. Ул Әҗебаба дигән чуаш авылында яшәгән, Төркиядә булып, мәшһүрлек казанган.

Хезмәттән күренгәнчә, Тау Иле, борынгы авылларның берсе булып, элек Тәвәнгир исеме белән дә аталган. Аның кечкенә һәм фәкыйрь булуы ниндидер бер газизнең бәддога кылуы белән аңлатыла. Икенче бер риваятьтә ул кешенең Казанны яклап сугышкан Өҗем баба икәнлеге сөйләнелә.

Тарихы Казан алынмастан элгәрге заманнарга барып тоташкан Бәчек авылына өч бертуган — Болгар яки Биләр шәһәреннән килеп утырган Бәчек, Энчек һәм Янчек бабалар нигез салган. Авыл зиратында Шәгъбан бине Әсәд исемле кешенең кабер ташында «Тарих тукыз йөз йитедә» дигән сүзләр сакланган. Ул милади 1490 елга туры килә.

Риваятьләргә күрә, Рысбуга авылына Рысбуга яки Рысбай исемле кеше нигез салган булса кирәк. Иң элек бу урынга баласы белән ниндидер чуаш хатыны килеп җир казып урнашкан, дигән хәбәрләр килеп җиткән. Элек авыл зиратында егермеләп борынгы кабер ташы булган. Ләкин аларны Кирмәле алпавыты Митонин 1600 елда пулат төзү өчен җыеп алган икән.

К.Насыйри Ачасыр авылына нигез салучының кем булуы мәгълүм түгеллеген яза. Риваятьләрдә аның чуаш кешесе булуы турында сөйләнелә. Хезмәттә «ачасыр» сүзенең чуаш теленнән «атасыз» дигәнне аңлатуы искәртелә. Авылда Тукмаш, Мәмәткол, Исай (Исәнгол), Габбас, Сәгъди, Таһир, Гайни муллалар имам булып торган. Кече Ачасыр авылына әнә шул Олы Ачасырдан күченеп утырганнар.

Сәлам авылы элек аны нигезләүче кеше исеме белән Ислам дип атала. Озакламый анда Себердән кайткан берничә рус гаиләсе урнаша. Тора-бара мөселманнар азаеп кала.

Китерелгән мәгълүмат башламында Бортас авылы дип куелса да, сүз Зөя каласы янындагы Борнаш дигән рус авылы турында бара. Ул элек мөселман авылы булып, аны Болгардан килгән Борнаш баба нигезләгән. Зөя руслар кулына күчкәч, халкы, Тәтеш өязенә күчеп, шул исемдәге авылга нигез салган. Борнаш баба белән килгән Сәет ага аерым авыл корып утырган. Тимер юлдагы Сәет станциясе — әнә шул авыл.

Болгар дәүләте җимерелгәндә вафат булган Арслан исемле бер кешенең Борындык баба исемле улы, Зөя якларына килеп, Борындык авылына нигез салган. Авыл элек бик бай булып, завод һәм фабрикалар, зур мәдрәсәләр тотканнар. Ләкин соңрак, байлар бөлеп, голяма беткән. Моның сәбәбе риваятьләрдә шулай сөйләнелә: Борындыкның Мансур исемле муллысы белән Тилчәледән Мортаза мулла арасында низаг чыга һәм соңгысы бәддога кыла. Авылда Мансур хәзрәттән соң Шәмгун, Мөхәммәдъяр, Вахит, Исмәгыйль муллалар имам булып торган.

Чуаш авылы Шигалидә элек мөселманнар яшәгән. Бу мәгълүмат авыл зиратында сакланып калган дүрт кабер ташындагы язулар белән раслана. Аларның икесе 1549, 1709 елларга карый. Өченчесендә «Тарих мең дә йөз утыз елда Бикбулат угылы Хуҗа Мирза дөньядин үтте...», — дип язылган, ягъни милади 1713 ел икәнлеге аңлашыла. Дүртенчесендәге «...тарих тукыз йөз дә иллектә Хаҗ угылы Шиши кафер тукышында шәһид булды» дигән сүзләр 1533 елда ниндидер сугышта һәлак булган кеше турында мәгълүмат бирә.

К.Насыйри Күкеш авылы турында риваятьләр сакланмавын яза. Зиратта 1533 елга караган бер кабер ташы барлыгын хәбәр итеп, анда «...тарих тукыз йөз иллектә Шумбак би угылы Җабирхан» дигән язулар барлыгын белдерә. Димәк, таш милади 1533 елда куелган.

Әлмән авылының барлыкка килүе хезмәттә аны нигезләгән, чуаштан мөселман булган Гыйльманның исеме үзгәрүгә бәйләп аңлатыла. Авылда имам булып Әбдери, Мәмәткол, Тимергали, Һибәтулла, Габдулла исемле муллалар торганлыгы хәбәр ителә. Хайван үләте беленә башласа, кияүгә чыкмаган кызларның авыл тирәли саба сөрүләре, электән калган мәҗүсилек гадәтенең шул вакытларга кадәр сакланып калуы турында сөйли.

Кармыш авылы Тәтештән килеп нигез корган Кармыш баба исеме белән аталган. Балалары ишәйгәч, ул аларны Чәнчас авылыннан чуаш кызларына өйләндергән. Авыл имамнары арасында Бакырчыдан күчеп килгән Мөрсәлим хәзрәтнең бик шөһрәтле булганлыгы әйтелә. Хәтта тирә-як авыллардан да килеп, төрле низаг-дәгъваларны аңардан хәл иттерә торган булганнар. Хезмәттә аның тарафыннан төзелгән солыхнамә, хатын алу хосусында шартнамәләрнең кайбер үрнәкләре китерелә.

Хәзер чуашлар яши торган Җамаш элек мөселман авылы булган. Ул икенче төрле Казаклар дип тә аталган. Соңыннан казаклар күчеп киткәннәр. Алар урынына Җамаш исемле чуаш килеп утырганга күрә, авылга аның исеме бирелгән. Мәчетләрен күрше Күкеш авылына күчереп салганнар. Авыл янындагы кабер ташларының берсендә «Тарих мең дә йөз унынчы елда», икенчесендә «Тарих мең дә йөз кырык алтыда ирде кем Янбулат угылы Савин дөньядин үтте» дигән язуларны укырга мөмкин икән. Димәк, сүз 1693, 1727 еллар турында бара.

К.Насыйри Кошман авылы элек русларныкы булып, анда мөселманнар Бишбатманнан күченеп килгән дип күрсәтә. Кошманда яшәгән руслар алар урынына Бишбатманга күчеп утырганнар. Моның сәбәбе мәгълүм түгел. Автор аннан соң, ни сәбәпледер, Кармыш баба һәм аның нәселе турында бәян итә.

Чабаксар шәһәреннән ерак түгел урнашкан ике чуаш авылының берсе Тутаркасе, икенчесе Юртакасе дип атала. Риваятьләргә караганда, алар элек татар авыллары булган. Чабаксар атамасының килеп чыгышы да чуашларның куаклыкны «чыбыксар» дип атаулары белән аңлатыла. Иван Грозный гаскәрләре шул якларны басып алганнан соң, Тутаркасе авылында яшәгән татарлар качып киткәннәр.

Кавал дигән чуаш авылы турында сүз алып барып, К.Насыйри андагы Рәхмәт исемле мулла турындагы риваятьне китерә. Кәрамәт иясе булган бу кеше йөкле киленена кыш көне идән астында кызарып пешкән җиләк ашаткан, имеш.

Хезмәт беренче мәртәбә «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга» (1926) җыентыгында, аннан соң К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»ендә (1953, 1956), «Әсәрләр»ендә (1971), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томында (1975), дүрт томлык «Сайланма әсәрләр»енең 3 нче томында (2005), «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык»та (2017) басыла.

Чыг.: Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Гали Рәхим карамагында. Казан, 1926; Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953, 1956; Насыйри К. Әсәрләр. Казан, 1971; Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1975. 2 т.; Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2005. 3 т.; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / фәнни ред. Ж.Миңнуллин; төз. Р.Исламов. Казан, 2017.

Р.Ф.Исламов.

АРХЕОЛО́ГИЯ, ТАРИ́Х ҺӘМ ЭТНОГРА́ФИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́, Казан университеты каршындагы фәнни җәмгыять (1878–1931). Аны оештыру турындагы карар 1877 елның июль-августында Казанда узган 4 нче Бөтенроссия археология съездында кабул ителә. Оештыручылар даирәсе (арада Н.Я.Агафонов, И.А.Бодуэн де Куртенә, Н.П.Загоскин, В.В.*Радлов)* һәм Устав әзерләү комиссиясе тәгаенләнә. Нигезләнү вакыты булып Россия Халык мәгарифе министры тарафыннан карар расланган 1878 елның 18 марты исәпләнә. Беренче әгъзалары сыйфатында аның 40 оештыручысы сайлана.

Җәмгыятьнең максаты — «элеккеге Болгар-Хәзәр һәм Казан-Әстерхан патшалыклары җирлегендәге рус һәм башка халыкларның үткәнен һәм бүгенгесен өйрәнү». 1897 һәм 1917 елларда Уставка өйрәнү өлкәсен киңәйтүне күздә тоткан төзәтмәләр кертелә. Шул ук вакытта аның төп максаты булып Казан төбәген һәм Көнчыгыш Россияне өйрәнү мәсьәләләре кала. Җәмгыять эшләре белән Совет (ике елга сайлана) идарә итә, Совет составына рәис, аның иптәше (урынбасары), 5 әгъза, сәркатип һәм казначы керә. Гомуми җыелышларда, әгъза булу-булмауга карамастан, һәркемнең дә катнашу хокукы була. Оешма «Археология, тарих һәм этнография хәбәрләре» фәнни журналын нәшер итә.

Җәмгыять эшчәнлеге дәверендә 600 дән артык кеше әгъза булып тора (Н.Я.Агафонов, Н.Ф.Высоцкий, Н.П.Загоскин, И.А.Износков, Н.Ф.*Катанов*, Д.А.Корсаков, П.И.Кротов, Н.П.Лихачёв, П.А.Пономарёв, Г.Н.Потанин, И.Н.Смирнов, А.А.Спицын,

Н.А.Фирсов, П.Д.Шестаков, С.М.Шпилевский, А.А.Штукенберг һ.б.), алар арасында татар галимнәре, мәгърифәтчеләре һәм төбәкне өйрәнүче эшмәкәрләр Шиһабетдин *Мәрҗани*, Каюм Насыйри, Мөхәммәтҗан *Аитов*, Гайнетдин Әхмәров, Һади Атласи да була.

1885 елда Каюм Насыйри җәмгыятьнең хакыйкый әгъзасы булып сайлана. Ул татар милләте тарихы һәм мәдәнияте мәсьәләләре буенча рус җәмәгатьчелеге алдында фәнни гомумиләштерүләр һәм нотыклар белән чыга, рус галимнәре белән даими аралаша, элемтәдә тора, аларга татар


Совѣтъ Общества
АРХЕОЛОГІИ, ИСТОРІИ И ЭТНОГРАФІИ

Каюм Насыйриның Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы дипломы.

милләте тарихы һәм мәдәнияте ядкәрләрен барлауда һәм аның тарихи үткәне турында хезмәтләр әзерләүдә ярдәм итә, үз эшчәнлеген археологик, тарихи, этнографик, эпиграфик һәм башка материалларны эзләп табу һәм фәнни әйләнешкә кертүгә юнәлдерә. Бу исә библиографик һәм кулъязма чыганакларны, халык авыз иҗатын өйрәнүне күздә тота. Галим археологик артефактлар, төрле авыллыклар, шәһәрлекләр, кирмәнчекләр, курганнар, кабер ташлары (эпитафияләр) һәм башка төрле тарихи-археологик истәлекләр турында мәгълүматлар туплый һәм аларның кайберләрен җәмгыятьнең журналында бастыра (кара: «*Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*»). Һәр җәйдә диярлек ул Казан губернасы Зөя һәм Цивильск (Чуел) өязләренең татар авыллары буйлап сәяхәт кыла, үткәннәр турында халык хәтерендә сакланган ядкәрләрне эзли һәм туплый, авыллар тарихы буенча мәгълүматлар җыя һәм аларны ачыклый, татар халкының этнографиясен өйрәнә. Хәзергечә әткәндә, кыр экспедицияләре оештыра. Беренчеләрдән булып, Зөя елгасының югары агымы төбәгендәге Казан ханлыгы чорыннан калган эпиграфик истәлекләрне өйрәнү эшенә керешә. Тарихи-археологик һәйкәлләрне өйрәнеп, К.Насыйри Казан татарлары чыгышлары белән Идел-Чулман Болгарстанының төп халкы варислары дигән нәтиҗәгә килә. Шулай ук аның аеруча мөһим бурычы татар халык авыз иҗаты һәм әдәбият үрнәкләрен — *җырларны*, *бәетләрне*, *әкиятләрне*, *мәкальләрне*, *табышмакларны*, *риваятьләрне*, *ырымнарны*, *ышануларны*, борынгы китапларны һәм кулъязмаларны, *шәҗәрәләрне* барлаудан гыйбарәт була. Шулай ук кара: *Археология*.

Әд.: Ильинский Л.К. Общество археологии, истории и этнографии при Казанском университете // Краеведение. 1929. № 9; История и историки в Казанском университете: К 125-летию Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете: Сборник научных статей и сообщений. Казань, 2005; Краткий очерк 8-летней деятельности Казанского общества археологии, истории и этнографии и его задачи. Казань, 1886; Пионтковский С.К. К 50-летию Казанского Общества археологии, истории и этнографии // Историк-марксист. 1929. Т. 11; Сидорова И.Б. Общество археологии, истории и этнографии при Казанском университете: Основные этапы истории // Краеведческие среды. Материалы заседаний, прошедших в Национальном музее

Республики Татарстан в 2003 г. Казань, 2004.

Р.В.Шәйдуллин.

«АРХЕОЛО́ГИЯ, ТАРИ́Х ҺӘМ ЭТНОГРА́ФИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́ ХӘБӘРЛӘРЕ́» («Император Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» («Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете»), фәнни журнал; *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* органы. 1878–1929 елларда Казанда рус телендә елга 3–6 саны чыга. Аерым 124 китаптан торган 34 томы дөнья күрә. Редакция комитеты әгъзалары катнашында җәмгыять сәркатибе мөхәррирлегендә нәшер ителә. Беренче мөхәррире — Н.П.Загоскин, төрле чыгарылышларның мөхәррирләре — Н.Ф.*Катанов*, А.Т.Соловьёв, А.С.Архангельский, Н.В.Никольский, П.В.Траубенберг, И.Н.Смирнов, Н.З.Тихов, К.В.Харламович һ.б. Редакция үз алдына Урал-Алтай дөньясын һәрьяклап өйрәнү бурычын куя.

Каюм Насыйри, Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы буларак, үзенең кайбер мәкаләләрен әлеге җәмгыятнең журналында бастыра. 1896 елда 13 нче том 5 нче чыгарылышта аның «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)» язмасы басылып чыга. Анда автор татар халык авыз иҗаты әсәрләреннең 417 үрнәге (28 *табышмак*, 244 *мәкаль*, 145 *җыр*) белән таныштыра. 1900 елгы 16 нчы томда К.Насыйри һәм П.А.*Поляков* авторлыгында «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» («Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов») хезмәте дөнья күрә. Казан губернасы авылларында К.Насыйри тарафыннан язып алынган 11 татар әкиятенең кириллица имлясындагы транскрипциясен Н.Ф.*Катанов* башкара, Поляков аларны рус теленә тәрҗемә итеп башка халыклар (башлыча рус) әкиятләре белән чагыштыра. Чагыштырулар фольклор аша төрле халыклар арасындагы багланышларны, үзара йогынтыны ачыклау юлында әһәмияткә ия.

Әд.: Альфонсов И.В. Указатель к «Известиям Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете» за 1878–1905 годы (т. 1–21). Казань, 1906; Воробьёв Н.И. Указатель к «Известиям Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете» за 1906–1927 годы (т. 22–33). Казань, 1928; Известия Общества археологии, истории и этнографии при императорском Казанском университете // Татар энциклопедиясе: 6 томда. Казан, 2010. 2 т.

И.Х.Хәлиуллин.

АРХИТЕКТУ́РА-ЭТНОГРА́ФИЯ КО́МПЛЕКСЫ Каюм Насыйри исемендә, төбәкне өйрәнү музее. Татарстанның Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылында урнашкан. 1997 елның 1 мартында, Каюм Насыйри исемендәге архитектура һәм этнография му-



Архитектура-этнография комплексы. Олы Ачасыр авылы.





Архитектура-этнография комплексы. Экспозицияләр. Олы Ачасыр авылы.

зее исеме белән Татарстан Берләштерелгән дәүләт музееның филиалы (2001 елдан *Татарстан Республикасы Милли музее*) буларак ачыла. 2010 елдан «Яшел Үзән районы музейлар берләшмәсе» филиалы итеп үзгәртелә.

Музей мәгърифәтче галим Каюм Насыйри туган һәм Казанга киткәннән соң кайтып йөргән нигездә, туганы Габдрахман Хөсәенов яңартып төзегән йортта оештырыла. Музей урнашачак бу йортны 1947 елда Олы Ачасыр авылы кешесе Габделгани Минзарипов К.Насыйри туганының килене Разия Хөсәеновадан сатып ала һәм Олы Ачасырга, үз туган нигезе янәшәсенә күчереп сала. Өйне күтәргәндә астан дүрт рәт ниргәсен яңага алмаштыра һәм кунак ягын ак як итеп эшли. Каралты-кураны яңадан салып, хуҗалыкны яңартканнан соң, өйләнеп, шул өйгә башка чыга, һәм гаилә анда 1982 елга кадәр яши. Татарстан Берләштерелгән дәүләт музее оештырган тарих-көнкүреш экспедициясе тарафыннан әлеге йортның тарихы ачыкланганнан соң, Г.Минзарипов 1982 елның декабрендә аны эчендәге һәм каралты-курадагы хуҗалык кирәк-яраклары белән бергә музейга бүләк итә.

Музей ачуда башлап йөрүче һәм аның фәнни концепциясе авторы — Р.Ә.Абзалина; сәнгать проекты авторы — О.Р.Гасыймов; утарның архитектура проекты авторы — И.А.Аксёнова. Музей оештыруның барлык эшләре ТАССР мәдәният министры урынбасары М.Т.Низамиев һәм министрлыкның тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау һәм файдалану идарәсе җитәкчесе Р.М.Вәлиев күзәтчелегендә алып барыла. Музей комплексының экспозиция мәйданы — 263,1 м^2, парк зонасы — 0,12 га тәшкил итә. Коллекциядә барлыгы — 1020 саклау берәмлеге, шул исәптән 989 төп берәмлек исәпләнә, 31 саклау берәмлеге ярдәмче фондта саклана.

Музей комплексына 19 йөз ахыры – 20 йөз башы гадәти татар утары: ике яклы алты почмаклы йорт, келәтләр, терлек абзарлары, яшелчә һәм җиләк-җимеш, алма бакчасы, бакча артында урнашкан ак мунча керә. Өсте ябулы әвеслектә татар крестьяннары хуҗалыгына хас булган көнкүреш әйберләре һәм эш кораллары, шул исәптән арба, чана, ат дирбияләре, кул һәм бала арбалары куелган, шунда ук утынлык урнашкан. Хуҗалык каралтыларыннан ашлык амбары, чыбылдыклы урын җәелгән «кияү келәте» бар. Тагын бер корылма галимнең табигать фәннәрен өйрәнгәндә тәҗрибәләр үткәрә торган остаханәсе итеп көйлән-





Архитектура-этнография комплексы. К.Насыйригa багышланган чаралардан күренешләр. Олы Ачасыр авылы.

гән. Анда гербарий кәгазьләре, дару үләннәре, туку станогы, киндер-җитен үсентеләренең эшкәртелмәгән үрнәкләре куелган.

Әлеге остаханәдәге сәке һәм өйнең түр ягына куелган кәнәфи, секретер, дивар көзгесе — К.Насыйри заманыннан калган җиһазлар. Секретерда К.Насыйриның ТР Милли музеендагы шәхси глобусы копиясе тора. Шулай ук анда галимнең нәсел агачы һәм Олы Ачасыр авылының Насыйри хезмәтләрендә искә алынган барлык имамнарының шәҗәрәсе куелган.

Түр якның түшәме биек, тәрәзәләрендә дулкынланып торган борынгы пыяла, мич төнлекләре металл каплавычлар белән капланган. Хатын-кыз, балалар ягы булган өлешендә сәке, түшәм асты тулысы белән чигүле ак кашага белән әйләндереп алынган. Йортның ике ягын берләштергән урталыкта госел бүлмәсе, кием-салым алыштыру урыны җайлаштырылган. Алгы яктагы мемориаль экспонатлардан өстәлдә самовар янында торган бер пар фарфор чынаяк («Кузнецов һәм К°» фирмасы тарафыннан татар сәүдәгәрләре заказы белән эшләнгән) һәм дивар сәгате — авыл имамы Габделхәбир Таһириныкы (1883–1975).

Музей, К.Насыйриның «Шифалы үләннәр» китабына нигезләнеп, яздан көзгә кадәр үләннәр җыя һәм алардан хуш исле чәйләр ясый. Аны комплексқа килгән кунакларга тәкъдим итә һәм, Татарстанда үткәргән төрле бәйрәм чараларында катнашып, 19 йөз ахыры – 20 йөз башы урта хәлле крестьян тормышын күрсәтә.

Музей директорлары: Р.С.Кадыйров (1997 елдан), Р.Ә.*Гатиятуллина* (2001 елдан; 2011 елдан — филиал мөдире).

Әд. Абзалина Р.А. Җәбәлстан. Ачык сырт Олы Ачасыр авылы тарихыннан сәхифәләр. Казан, 2021; Объекты культурного наследия Республики Татарстан. Административные районы. Иллюстрированный каталог / под ред. А.М.Тарунова. М., 2021.

Ф.Г.Камальтдинова.

АСТРОНО́МИЯ (борынгы грек теленнән á*stro* — йолдыз һәм nó*mos* — закон), күк җисемнәренең (планеталар, йолдызлар, астероидлар һ.б.), аларның системаларының һәм тулаем Галәмнең хәрәкәте, төзелеше, барлыкка килүе, үсеше турындагы фән.

Астрономия — иң борынгы фәннәрнең берсе. Ул кешелек җәмгыятенең гамәли ихтыяҗларыннан барлыкка килә. Кояш, Ай һәм кайбер йол-

дызларның чыгу-калкуы һәм баюы, Кояш белән Ай тотылуларның әледән-әле кабатлануы белән бәйле төп күренешләр турында язма тарихка кадәрге кешеләр дә белгәннәр. Иң борынгы язма чыганакларда астрономик күренешләрне тасвирлау, якты көк җисемнәренең чыгу һәм бату вакытын алдан әйтү өчен гади исәп-хисап схемалары, вакытны исәпләү һәм календарь алып бару ысуллары очрый. Борынгы цивилизацияләр үзләреннән соң көк җисемнәренең хәрәкәт закончалыкларын белүләрен раслаучы күпсанлы астрономик артефактлар калдырганнар. Астрономия борынгы Вавилонда, Мисырда, Кытайда, Һиндстанда һәм Грециядә, урта гасырлар мөселман Көнчыгышында уңышлы үсеш алган.

Татар халкының көндәлек тормышына астрономик күренешләрне өйрәнү традицияләре Идел буе Болгар дәүләте чорыннан керә башлый һәм Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверләрендә таралыш ала. Урта гасырлар чыганакларында болгар астрономы, мәчет әһеле Мәсгуд әл-Болгари турында искә алына. Ул астрономик җайланмалар ярдәмендә намаз вакытын билгеләгән һәм йолдызлар буенча һава торышын алдан әйтә белгән. Алтын Урда шагыйре Сәйф Сараи үзенең «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасына (1394) мондый юлларны кертә: «Гөлдерсен, Җир Кояш тирәли әйләнгәндәй, Сөһәйлгә әйләнеп кайтты». Бу Коперникка кадәр 150 ел алдан әйтелгән фикер була. Татар шагыйре Котбның 1342 елда иҗат ителгән «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында Җирнең үз күчәре тирәсендәге хәрәкәте турында бик ачык итеп язылган.

19 йөздә татар халкының астрономия белән кызыксынуы башлыча вакыт, календарьлар һәм күктәге күренешләрне теркәү белән бәйле була. Татарларда мөселман ай календаре белән берәттән 12 еллык циклы кояш календаре да гамәлдә йөри. Мәсәлән, Каюм Насыйри үз календарьларына һәр ел билгеле бер хайван белән бәйле булган Кытай гороскобын кертә. Мондый практика 18 йөз уртасындагы кулъязма татар календарьларында ук очрый. Шул ук вакытта татарларның да кайберләре, йолдызчылык (астрология) белән мавыгып, зодиакның төрле билгеләренә һәм йолдызларның (планеталарның) кеше язмышына йогынтысына ышана. Госманлыларның Казанда басылган «Йолдыз-намә» китабының кулъязма вариантлары татарлар арасында кулланышта була. Казан университеты профессоры Н.Ф.*Катанов*, аларның астрология белән кызыксынуларын искәртеп: «Татарларның күпчелеге йолдызчылык турындагы китаптан файдалана. Ә бит мөселманлык һәм төрле гороскоплар, күрәзәчелек һәм башкалар бер-берсенә туры килми торган әйберләр», — дип яза. К.Насыйри үзенең календарьларында астрономия буенча төрле кызыклы мәгълүматлар китерә. Шулар арасында «Көсуф вә хөсуф» («Ай һәм кояш тотылу») дип аталган мәкаләсе аерым әһәмияткә ия. Әлеге хезмәтендә ул бу күренешләрне табигать законнары нигезендә аңлатырга тырыша. Оста каллиграф буларак, ул астрономик карталар да сыза һәм бастыра. Шулай ук «*Буш вакыт*» исемле парчаларында җирнең магнит кыры, һава һәм аның сыйфатлары һәм башка астрономик күренешләр турында яза.

Чыг.: Насыйри К. Буш вакытларда укырга сүзләр. Казан, 1867; Шул ук. Көсуф вә хөсуф хакында Чәгъминидән бераз гыйбарәт // Календарь 1883 нче елга. Казан, 1882.

Р.В.Шәйдуллин.

«АТАКЛЫ́ МӘГЪРИФӘТЧЕ́-ДЕМОКРА́Т КАЮ́М НАСЫЙРИ́», кара: «*Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри*».

АХУ́Н Садри Сәлах улы (16.03.1903, Екатеринбург шәһәре – 21.06.1990, Мәскәү), сынчы, педагог. ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1944, 1950), ТАССРның халык рәссамы (1949). ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1936) һәм рәисе (1940–1950). Нәсел тамырлары Казан губернасының Лаеш өязе (хәзерге Теләче районы) Олы Мәтәскә авылына барып тоташа.

Чиләбедә җәдит мәдрәсәсен (1915) һәм дүрт класслы коммерция училищесын (1919), Урал сәнгать-сәнәгать техникумын (ташны уеп бизәк ясау бүлеге, 1927), Ленинград пролетар сынлы сәнгать институтын (скульптура бүлеге, 1931) тәмамлый. Р.Р.Бах, А.Т.Матвеев, Л.В.Шервуд шәкерте. 1931–1951 елларда Казан сәнгать училищесында укыта, 1949 елдан скульптура бүлеген җитәкли (шул чорда укыган шәкертләре Н.И.*Адылов*, В.М.Маликов, Р.Х.Нигъмәтуллина 1960–1980 елларда татар скульптурасы үсешенә зур өлеш кертәләр). 1951 елдан — Мәскәүдә: Мәскәү технология институтының композиция кафедрасы мөдире, профессоры (1966–1974).

Беренче профессиональ татар сынчыларының һәм 1930–1950 елларда совет скульптура сәнгатендә әйдәп баручы осталарның берсе буларак, милли сынлы сәнгать үсешенә зур өлеш кертә. Күренекле сәнгать белгече Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, иҗатына югары бәя биреп, аның татар профессиональ скульптурасына нигез салучы булуына басым ясый. Сынчының иҗаты югары профессиональлеккә, татар халкы сәнгате һәм рус реалистик



С.С.Ахун

скульптурасы (П.К.Клодт, Ф.П.Шубин, П.П.Трубецкой), шулай ук Көнбатыш Европа сәнгате (Огюст Роден) традицияләрен чагылдыручы мөстәкыйль идея-образ концепциясенә нигезләнә.

С.Ахун үз иҗатында станлы скульптурага өстенлек бирә, гипс, мәрмәр, агач, фарфор кулланып, портрет һәм тематик композиция жанрларында эшли. Психологик портрет өлкәсендә танылган оста татар, рус һәм дөнья мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре образларының тулы бер галереясын тудыра. Габдулла Тукай (1929, 1938), Һади Такташ (1931), Каюм Насыйри (1941), Нәҗип Җиһанов (1941–1945) һ.б.ның бюстларын; Ромен Роллан барельефын (1938); гипстан «Анри Барбюс», «Ленин», «Энгельс» барельефларын (1938–1940), мәрмәрдән Салих Сәйдәшев (1957), А.М.Бутлеров (1965), Максим Горький (1968), Анджела Дэвис (1971), Рабиндранат Тагор (1974) һ.б.ның скульптур портретларын иҗат итә.



С.С.Ахун.
Каюм Насыйри бюсты.
Гипс. 1941.

Каюм Насыйриның ТР Милли музеенда саклана торган бюсты бөек мәгърифәтченең портретына нигезләнеп эшләнгән. Сынчы, аның холык, төс-кыяфәт үзенчәлекләрен чагылдырып,

мәгърифәт таратучы шәхес образын тудыра. Каюм ага кырпулы бүректән, сакал-мыеклы, заманының яшәеш шартларына разый мөнәсәбәте чагылган ачык карашлы.

Советлар Союзы Геройлары М.Воронков, И.Ижукин (икесе дә — 1945), Муса Җәлил (1957), Әмәтхан Солтанның (1974) портрет-бюстлары өчен сынчы монументаль скульптура жанрын сайлый. В.И.Ленин һәйкәле авторы (1957, Череповец шәһәре). Аның тарафыннан (сынчылар Л.Е.Кербель, Л.М.Писаревский һәм архитектор Л.Н.Павлов белән берлектә) иҗат ителгән һәм 1958 елда Казанда куелган Габдулла Тукай монументаль бронза һәйкәле аеруча уңыш казана.

Казанда яшәгән елларында станлы жанрда күп кенә композицияләр иҗат итә. Аларның тематикасында, образларында, форманың декоратив бирелешендә милли үзенчәлекләр чагылыш таба. Остазның материалны эшкәртүдәге югары культурасы, фактуралы әвәләү динамикасы, купшы формалар, детальләрне җентекләп бирүе образларның поэтик һәм музыкаль гармониясен тудыра. Татар сынчылары арасында ул, беренчеләрдән булып, милли темага мөрәҗәгать итә. «Лачын авы», «Дала җыры» (икесе дә — 1938–1940) кебек станлы жанр композицияләрендә сынчы татар милли киемнәрен, бизәк үрнәкләрен, урта гасырлардагы татар халкына хас үзенчәлекләрне чагылдыра. Шәрекъ темасы Ганҗәви Низаминың «Арысланны үтерүче Хөсрәү» һәм «Мәҗнүн кәҗәболаннар арасында» (Бакудагы Низами музее; икесе дә — 1939, скульптура) әсәрләрендә чагылыш таба.

Казан паркларындагы «Дөньяда хезмәт хакимлек итәчәк!» һәм «Балыкчы» фонтаннары, «Динамо» стадионы каршындагы «Теннисчы кыз» һәм «Ядрә ыргытучы» фигуралары (барысы да — 1934–1937), Татар академия театры интерьерындагы Галиәсгар Камал барельефы (1941–1945) кебек монументаль бизәлеш сәнгате әсәрләре авторы буларак та билгеле.

Студент вакытында урал асылташларыннан (яшма, малахит, зөбәрҗәт, еланташ, ахак) уеп ясалган нәфис эшләнмәләр циклы өчен Парижда уздырылган Халыкара күргәзмәнең Зур алтын медаленә лаек була (1925). Бөтенсоюз Рәссамнар берлегенең Мәскәү оешмасы күргәзмәләрендә катнаша (1950–1980).

Әсәрләре Казанда ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, М.Горький һәм Ф.Шаляпин музеенда һәм башка оешмаларда саклана.

Әд.: Бреннерт В. Садри Ахун. Казань, 1945; Дульский П.М. Скульптор Садри Ахун // Искусство. 1936. № 1; Народные художники Татарской АССР. Казань, 1980.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.


Ә

«ӘБУГАЛИСИНА́ КЫЙССАСЫ́», сатирик алым белән кыйсса жанрында язылган фантастик формадагы проза әсәре. 1872 елда Каюм Насыйри тарафыннан ижат ителә һәм 1881 елда Казан университетының басмаханәсендә дөнья күрә.

Кыйсса кереш өлештән («Әбелхарис белән Әбугалисинаның балалык вакытлары һәм укулары») һәм дүрт кыйссадан («Әбелхарис белән Багдад падишаһының кыйссасы», «Әбугалисина белән Мисыр падишаһының кыйссасы», «Бохара падишаһы кыйссасы», «Кирман падишаһы белән Әбугалисина кыйссасы») тора; ахырда Әбугалисинаның вафаты бәян ителә. Әсәрнең эчтәлеге бертуган игезәк Әбугалисина белән Әбелхаристың үз башларыннан кичкән мажараларны бәян итүдән гыйбарәт. Кыйссада искәртелгәнчә, Әбугалисина төрле могҗизалар күрсәтергә сәләтле була: җил чыгара, шәһәрдәге барлык утларны бер үк вакытта сүндерә, таякны атка әверелдерә ала һәм башка тылсымлы гамәлләр кыла. Әбугалисина һәм Әбелхарис белемле булулары белән һәрвакыт җиңеп чыгалар, падишаһларны һәм аларның ялчыларын мәсхәрәгә калдыралар.

Мөселман халыклары авыз ижатында киң таралган Әбугалисина белән Әбелхаристың фантастик мажараларын беренче тапкыр 16 йөзнең 2 нче яртысында төрек дәрвише Хәсән Мәдхи барлый һәм үзеннән өстәп китап итеп төзи. Ул аны төрек солтаны Мурат III гә (1546–1595) бүләк итә; ләкин, халык чыганакларыннан гына файдаланмыйча, үзеннән дә бик күп нәрсәләр өстәве сәбәпле, солтан китапны кабул итми. К.Насыйри исә төрек язучысы Зыятдин Сәет Яхъяның И.Г.Габдуллин тарафыннан 1864 елда Казанда нәшер ителгән «Кәнҗинәи хикмәт» әсәрен, гади халык аңларлык дәрәҗәдә тәрҗемәләп, «Рәисе әл-хөкәмаи Әбугалисина кыйссасы димәклә мәшһүр тәхаййелатнең тәрҗемәсе» исеме белән Казанда бастырып чыгара. Тәрҗемә итүнең сәбәбен ул түбәндәгечә аңлата: «Ошбу «Әбугалисина кыйссасы» 1281 [1864] нче елда Казан әһалисеннән [кешеләреннән] бер адәмнең һиммәте [тырышлыгы] белән бер мәртәбә табгы кылынмыш [басылган] иде. Ләкин гыйбарәтендә [текстында] гарәп вә фарсы сүзләре күплек сәбәпле, бәгъзе адәмнәр файдасыннан мәрхүмнәрдер. Чөнки гарәп-фарсы белмәгәннәр өчен гыйбарәте авырдыр. Шундаен кешеләр бар: кыйссаның мәзмунын [эчтәлеген] вә мәгънәсен фәһемләү түгел, хәтта гыйбарәтен генә дә читенлек белән укыйлар. Бәс, гарәп-фарсы аз белгән адәмнәрдән кыйсса вә хикәят укырга ихласы бар кешеләр өчен ошбу «Әбугалисина кыйссасы»н, халык аңларлык итеп, рус мәмләкәтендәге мөселманнар теленә тәрҗемә кылсам икән, дип, күп заманнан бирле күңелемдә бар иде».

Кыйссада Әбугалисина турында Урта Азия мөселман халыклары арасында йөргән күпсанлы хикәя һәм риваятьләр туплана. Эчтәлегенең реаль шәхес, бөек галим, фәлсәфәче, табип, астроном, шагыйрь, музыкант Әбу Гали Хөсәен ибне Габдуллаһ (980–1037) биографиясе белән бәйләнеше юк дияр лек.


رئيس الحكما

ابو علي سينا

قصه‌سي ديمكله مشهور تخيلات‌نك ترجمه‌سي

عبد الكريم ملا عبد الناصر اوغلي‌نك ترجمه وتصنيفاتندندر

الثانيه مرتبه باصلمشدر

بر مقدمه ودورت فصل وبر خاتمه اوزره ترتيب قيلندي

بوكتاب قزان اوتيوز بر سنه‌سي‌نك طبع خانه‌سنده واقعه اولمشدر. قزان اوبزي تورال ايشي آوي‌نك اسماعيل بحم الدين اوغلي شمس الدين‌نك خراجاتي ايله ١٩٠٥ جي سنه‌ده

Дозволено цензурою С. Петербургъ, 10 ноября 1904 г.

КАЗАНЬ.
Типо-литографія Императорскаго Университета.
1905.

К.Насыйри. «Әбугалисина кыйссасы». Казан, 1905.

Әсәр кабат 1889, 1894, 1898, 1900, 1905 елларда дөнья күрә. Совет хакимияте чорында язучы Гасыйм *Лотфи* әсәрне, зур яшьтәге балалар өчен кыскартып эшләп, 1947, 1950, 1953, 1957, 1975 елларда нәшер итә. 2015, 2019 елларда ул кабат бастырыла. Кыйсса К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1945, 1953, 1956), «Әсәрләр»енә (1971), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең беренче томына (1974), дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең беренче томына (2003) урнаштырылган. Әсәрнең рус теленә тәрҗемәсе аерым китаплар булып 1957, 1981 елларда басылып чыга, «Сайланма әсәрләр»енә кертелә (1977). Ул 1986 елда башкорт телендә дә дөнья күрә.

Чыг.: Насыйри К. Әбугалисина кыйссасы. Казан, 1881; шул ук. Әбүгалисина. Казан, 1947; шул ук. Әбүғәлисина. Өфө, 1986; шул ук. Абугалисина. Казань, 1957.

Әд.: Гали М. «Әбугалисина кыйссасы»на аңлатма // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; Халит Б. «Әбугалисина кыйссасы» турында // Совет әдәбияты. 1940. № 8; Хәмидуллин Ә.К. Насыйриның «Әбугалисина кыйссасы»нда акыл культы // Мәгариф. 1994. № 2.

Р.Ф.Исламов.

ӘДӘБИ́ ТӘНКЫ́ЙТЬ, әдәби иҗат төре, әдәбият белеменең бер тармагы; әдәби әсәргә фәнни-эстетик анализ ясау һәм бәя-аңлатма бирү.

Әдәби тәнкыйтьнең барлыкка килүе татар иҗтимагый фикере үсеше белән бәйле. 18 йөз ахыры – 19 йөз башында дини әдәбият һәм фәлсәфә тармагында Габденнасыйр Курсавиның дөньяви гыйлемнәр үзләштерү ире ге белән бәйле фикерләре, әдәби һәм тарихи ядкәрләрне жыю һәм өйрәнү өлкәсендә Шиһабетдин Мәрҗани һәм Хөсәен Фәезханов хезмәтләре әдәби тәнкыйтьнең башлангычы булып тора. Әлеге галимнәрнең иҗат эшчәнлекләре, башлыча дини әдәбият һәм фәлсәфи юнәлешләрдә алып барылуы һәм хезмәтләренең күпчелеге татар халкына аңлаешлы тел язылуы сәбәпле, татарларның иҗтимагый фикере үсешенә житди йогынты ясый алган.

19 йөзнең соңгы чирегендә Каюм Насыйри әдәби, фольклор һәм тарих ядкәрләрне жыю, аларны фәнни яктан тикшерү һәм тәнкыйди эшкәртү буенча киңкырлы эшчәнлеге белән татар әдәбиятында тәнкыйди фикер үсешендә зур роль уйный. Урта гасыр-

лар татар әдәбияты, Шәрекътән килгән традицияләрне Көнбатышның әдәби практикасы белән кушу омтылышы юлындагы беренче адымнар аның тарафыннан ясала. Галимнең әдәби-гыйльми эшчәнлегендә әдәби тәнкыйтьнең жанрлары (бәяләмә, тәгъзия, мәкалә һ.б.), аларның сыйфатлары ачыклана башлый. Календарьларында дөнья күргән фәнни һәм публицистик мәкаләләре татар әдәби тәнкыйте һәм әдәбият белеменең нигезен тәшкил итә. Хезмәтләрендә Габдрахман Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый кебек шагыйрьләрнең ижат мирасын бәяләүнең беренче үрнәкләре очрый. Г.Кандалыйның «Сәхипҗамал», «Бәдыйга», «Фәрхи» поэмаларын тел-стиль һәм төзелеш үзенчәлекләре ягыннан фәнни шәрехләү омтылышы ясала. «Кабуснамә» (1881) китабының «Шигырь вә шагыйрьләр әхвале бәянында» бүлегендә К.Насыйри шигырь, аның эчтәлеге, укучыларга атап язылган булуы турында сүз алып бара. Ул шулай ук кешенең матурлыкны күрә һәм бәяли белү сәләтен югары бәяли. Энциклопедистик характердагы «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884) әсәрендә: «Чәчәкләр матурлыгын күреп сокланмаган, музыка, җыр белән кызыксынмаган кеше нинди кеше була инде ул», — дип яза. Халык авыз ижаты, тел, әдәбият тарихы һәм әдәбиятның башка мәсьәләләренә караган әлеге җыентыкның соңгы бүлегендә К.Насыйри башта халык авыз ижаты жанрларына, шигырьләрнең, гомумән, матур әдәбиятның әһәмиятенә туктала, аннары әдәби күренешләргә шактый тулы аңлатмалар бирә.

Фатих Әмирхан «Әдәбиятка гаид» мәкаләсендә К.Насыйриның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге ролен билгеләп: «Әдәбиятыбыз күп гасырлар Шәрык тәэсире белән килгәннән соң, акрын гына гареп (Европа) тәэсире астына да керә башлыйдыр. Әдәбиятыбызның бу периоды мәрхүм Габделкаюм Насыйри белән башланадыр. Насыйри гарәпчә вә русча яхшы белгән зыялы бер зат булганлыктан, әсәрләрендә Шәрыктан күп нәрсәләр истифадә иткән шикелле — рус әдәбиятыннан да файдаланадыр... Насыйри үзенең озак вә фәүкыльгадә [гадәттән тыш] тырышлык белән иткән хезмәте аркасында, халык тарафыннан вакытында тәкъдир ителмичә генә, Габдулла Тукай һәм әдәби тәнкыйть татарларга бик күп нәрсәләр һәдия иткән. Ул, иң әүвәл татарларны рус теле белән белештермәкче булып, словарь «Әнмүзәҗ» тәркип итүче [төзүче], ул, иң әүвәл татарларга үзләренең бер телләре бар икәнен белдертер өчен — «Ләһҗәи татар» вә «Фәвакиһел җөләса» тәклиф итүче [боеручы]. Вә ул ук иң әүвәл әсәрләрен татарча яза башлап, һәр язу таныган кеше истифадә итәрлек тарызда [файдаланырлык рәвештә] ясаучы булды», — дип ассызыклый.

К.Насыйриның дөньяви ижтимагый-эстетик фикерләү рәвешендә язылган теоретик хезмәтләре һәм дәреслекләре, күп санда басылган китаплары, аларга язылган сүз башлары һәм 24 ел дәвамында чыгып килгән календарьлары татар әдәби тәнкыйтен үстерүгә, халык өчен зарарлы идеяләр белән сугарылган әсәрләрне фаш итүгә һәм укучыларны шул идеяләрдән саклау юлларын эзләүгә зур өлеш кертә. Галимнең тәнкыйди реализмы нигезендә кешене әхлакый камиллеккә өндәү, башкаларга файдалы булырга чакыру ята. Моны Көнчыгыш тарихын һәм мәдәниятен өйрәнгән галимнәрнең (В.В.Григорьев, Н.Ф.Катанов, В.Д.Смирнов һ.б.) К.Насыйри хезмәтләренә карата ясаган күзәтүләре, бәяләмәләре, тәнкыйть мә-

каләләре һәм төзегән библиографияләре раслый.

К.Насыйриның теоретик карашлары, хезмәтләре һәм бәяләмәләре татар әдәби тәнкыйтенең мөстәкыйль фән буларак формалашуына ярдәм итә. 20 йөз башында татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәч, Ризаэтдин Фәхретдин, Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Җамал Вәлиди, Габделбари Баттал, Галимҗан Ибраһимов һ.б., К.Насыйриның дәвамчылары буларак, мәкаләләрендә һәм бәяләмәләрендә әдәби тәнкыйткә теоретик нигез салалар, әдәбиятның чынбарлыкка мөнәсәбәте, халыкчанлыгы һәм милли үзенчәлеге кебек мәсьәләләргә ачыклык кертәләр, аның үз жанрларын булдыралар. Әйтик, Ибраһим Нуруллин Г.Тукайның әдәби-эстетик карашларының 19 йөз татар мәгърифәтчелеге әсәрләренә нигезләнүен игътибарга ала. Аның фикеренчә, «шагыйрь халыкны наданлык, караңгылык баткагыннан чыгаруны үз алдына максат итеп куя».

Әд.: Әмирхан Ф. Әдәбиятка гаид // Сайланма әсәрләр. Казан, 1958, 2 т.; Гайнуллин М. Габдулла Тукай һәм әдәби тәнкыйть // Совет әдәбияты. 1946. № 4; Гыйләҗев Т. XIX гасырның соңгы утызъеллыгында тәнкыйди фикер үсешендә К. Насыйри һәм И. Гаспралы // X. Uluslararası Türk Sanatı, Tarihi ve Folkloru Kongresi (Sanat etkinlikleri) = X Международный конгресс «Искусство, история и фольклор тюркских народов» = «Төрки халыклар сәнгате, тарихы һәм фольклоры» X Халыкара конгрессы = X International Turkic art, history and folklore congress (art activities). Казань, 2018.

Р.В.Шәйдуллин.

ӘКИЯ́Т, халык авыз иҗатының борынгы жанрларыннан берсе, ул уйдырмаларга нигезләнгән мавыктыргыч, маҗаралы, күбесенчә чәчмә, сирәгрәк тезмә формадагы эпик әсәр. Әкиятләрдә реаль һәм фантастик алым-чаралар ярдәмендә сурәтләнгән кешеләр, хайваннар, мифик образлар аша халыкның үткәне, киләчәккә хыял-омтылышлары чагылдырыла. Алар, нигездә, өч төргә бүлеп карала: хайваннар турындагы әкиятләр, тылсымлы әкиятләр һәм көнкүреш әкиятләре.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, өйрәнүгә һәм дөньяга чыгаруга аеруча зур игътибар бирелә. Ул, татар халык *җырларын*, *бәетләрен*, *мәкальләрен*, *сынамышларын*, *табышмакларын*, *риваятьләрен*, *ырымнарын*, *ышануларын* барлау белән бергә, Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендәге татар авылларында халык арасында йөргән әкиятләрне җыю һәм туплауны мөһим бурычы дип саный, җыйналган әкиятләрнең күпчелек өлешен 1900 елда П.А.*Поляков* һәм Н.Ф.*Катанов* ярдәмендә *«Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»*ндә бастыра. Әлеге җыентыкка 11 әкият («Аю белән төлке», «Байдек», «Гакыллы угыл», «Гөлнәзек», «Мәче белән аю», «Өч угыл», «Салам Торхан», «Сандугач белән бытбылдык», «Төлке», «Үги кыз», «Юләр угыл») керә. Әдипнең 1954 елда дөнья күргән әкиятләр җыентыгы 8 әсәрдән («Аю белән төлке», «Байдек», «Гөлнәзек», «Мәче белән аю», «Өч угыл», «Салам Торхан», «Төлке», «Үги кыз», «Юләр угыл») тора. 2005 елда нәшер ителгән дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең өченче томы 14 әкиятне («Аю берлән төлке», «Әләкче», «Әфсәнәи Гөлрох вә Камәржан — Гөлрох вә Камәржан әкиятләре», «Байдек», «Гакыллы бала» «Гөлнәзек», «Җүләр угыл», «Мәче берлән аю», «Өч угыл», «Салам Торхан», «Төлке», «Үги

кыз», «Шүрәле») үз эченә ала. Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә аның «Әләкче», «Төлке белән әтәч», «Шүрәле» әкиятләренең кулъязмалары саклана.

К.Насыйри җыйнап бастырган әкиятләрдә гакыл, тырышлык, уңганлык һәм пөхтәлек кебек күркәм сыйфатлар мактала һәм, киресенчә, ахмаклык, әләкчелек, көнчелек, наданлык, ялкаулык ише тискәре сыйфатлар нык гаепләнә. Андый сыйфатлар күбрәк көнкүреш һәм хайваннар турындагы әкиятләрдә урын ала. Ул җыйган кайбер әкиятләрдә («Гөлнәзек», «Өч угыл», «Үги кыз») дию, су иясе, убырлы карчык кебек мифик затлар да катнаша, ләкин алар белән көрәштә әкият геройлары көч һәм тылсым ярдәмендә түгел, ә изгелек, намуслылык, тапкырлык, тугрылык кебек сыйфатлар аша җиңүгә ирешәләр. Әдип еш кына мәкальләрне әкиятләргә йомгак ясау, геройларның әхлакый сыйфатларына бәя бирү өчен файдалана. Мәсәлән, «Байдек» әкиятенең персонажы урлап алып кайткан малның (хәситәнең) рәхәтен, файдасын күрә алмый, барысын да әрәм-шәрәм итеп бетерә. Әкият «ырыкныкы — шырыкка» дип тәмамлана. Шулай ук кара: «*Әкиятләр*».

Әд.: Җамалетдинов Р. Әкиятләр // Фольклор жанрларын анализлау. Казан, 1989; Урманче Ф. Әкият (һәм миф) // Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А–Г). Казан, 2008; Насыров А.К., Поляков П.А. Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Казань, 1900. Т. XVIII. Чыг. 4–6; Хабибуллина Д.А. Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов в «Известиях Общества археологии, истории и этнографии» // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: Сборник статей итоговой научной конференции научных сотрудников Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ (г. Казань, 19 мая 2022 г.). Казань, 2022. Вып. 14.

Р.В.Шәйдуллин.

«ӘКИЯ́Т», 1 нче балалар бакчасы. ТР Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәрендәге мәктәпкәчә белем бирү йорты, ТР Мәгариф



«Әкият» балалар бакчасы.

һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2019). 2006 елда ачыла. 2024 елда 99 бала тәрбияләнә, 15 педагог эшли.

«ӘКИЯТЛӘ́Р», халык авыз иҗаты әсәрләре җыентыгы. 1954 елда Казанда дөнья күрә. Төрле елларда Каюм Насыйри тарафыннан татар авылларыннан җыеп тупланган. 8 әкиятне («Байдек», «Үги кыз», «Өч угыл», «Гөлнәзек», «Салам Торхан», «Төлке», «Аю белән төлке», «Мәче белән аю») үз эченә ала. Шул ук эчтәлек белән 1960 елда кабат бастырыла. Бу әкиятләр К.Насыйриның 1953, 1956, 1974 (1 нче том) елларда, 2005 (3 нче том) елларда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр»енә дә кертелә. Аларның русча тәрҗемәләре 1977 елда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»ендә («Избранные произведения») урнаштырыла.



К.Насыйри. «Әкиятләр». Казан, 1954.

Әсәр.: Насыйри К. Әкиятләр. Казан, 1954; шул ук. Әкиятләр. Казан, 1960; Насыри К. Избранные произведения. Казань, 1977.

Р.Ф.Исламов.

ӘЛМИ́НОВ Байназар Мостафа улы (14.08.1909, Самара губернасының Бозаулык өязе Кызыл Мәчет авылы – 31.10.1976, Казан), график, китап графикасы өлкәсендә әйдәп баручы осталарның берсе. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), Рәссамнар берлеге әгъзасы (1939).

Татар-башкорт техникумын (1930, Уфа), Пенза сәнгать-педагогия техникумын (1934) тәмамлый. 1934–1935 елларда Куйбышев шәһәрендә «Кызылармеец» татар газетасында рәссам булып эшли, 1935 елдан — Казанда, Татарстан китап нәшриятында бизәлеш мөхәррире, 1947 елдан — шунда ук бизәлеш редакциясе мөдире. Шәриф Камалның «Акчарлаклар», «Таң атканда», «Сулган гөл», «Бәхет эзләгәндә», «Уяну» әсәрләренә иллюстрацияләр ясый (1940–1949), башка әдипләрнең дә китапларын бизи. Әдәби әсәрләрнең сюжет-хикәяләү юнәлешен, тарихи һәм этнографик үзенчәлекләрен төгәл чагылдыра. 1936 елдан Габдулла Тукай әсәрләрен («Шигырьләр», 1936; «Шигырьләр. Әкиятләр», 1941; «Шүрәле», 1937, 6 нчы басма, 1969) иллюстрацияләү белән шөгыльләнә. 300 дән артык китап бизи, шулар арасында татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләре, дәреслекләр («Әлифба», 1960 елларда берничә тапкыр басыла) бар.

Бөек Ватан сугышы елларында, татар рәссамнарыннан беренчеләрдән булып, фашизмга каршы агитация плакатлары яза. Станлы нәкышь өлкәсендә дә эшли, жанрлы композицияләр, тушь, гуашь һәм акварель белән язылган пейзаж һәм портретлар авторы. Психологик портрет остасы; татар мәдәнияте эшлеклеләре образларының тулы бер галереясын (Шәриф Камал, Җәүдәт Фәйзи, Салих Сәйдәшев, Нури Арсланов, Нәби Дәүли, Сибгат Хәким, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Кутуй; документаль материаллар нигезендә — Каюм Насыйри, Фатих Әмирхан һ.б.) иҗат итә.

Нәкый Исәнбәт истәлекләренә караганда, Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган чара уздыру алдыннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Мөхәммәт Гайнуллин шуннан 20 ел чамасы элек, 1925 елның февралендә, галимнең 100 еллыгына нисбәтле җыелышта аның Госман *Арсланов* эшләгән портретына карата Фатих *Әмирханның*: «Бу рәсем белән мин мотлак разый түгелмен! Ул мин күзаллаган Каюм Насыйрига бер дә охшамаган» дигән сүзләрен һәм җыелыш президиумының «Каюм Насыйриның яңа рәсемен ясатырга!» дип карар чыгаруын искә төшерә һәм портрет эшләтү чарасына керешә. Башта ул галим-

нең этнография буенча хезмәтләре белән танышып чыга. Аннары Әлминовка мөрәҗәгать итә. Н.Исәнбәт рәссамга К.Насыйрины затлы киемнәрдә тасвирларга киңәш бирә. К.Насыйриның портреты иҗат ителү тарихын рәссам үзе утыз елдан соң түбәндәгечә искә ала: «1944 ел. Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты Каюм Насыйриның 120 еллыгына хәзерләнә иде. Институтның шул чактагы директоры Мөхәммәт ага Гайнуллин мине чакырып алды да: «Каюм Насыйриның портретын ясарга кирәк иде. Каюм Насыйриның кем икәнен яхшы беләсез. Аның тышкы кыяфәте, кигән киемнәре, гадәтләре, үз-үзен тотышы һәм башкалар турында аны белгән кешеләрнең истәлекләреннән укырсыз һәм, ниһаять, менә сезгә киңәшкә язучы Мөхәммәт Гали абзыегыз. Эш барышында килеп чыга торган бөтен сорауларны хәл итүдә ул сезгә булышыр», — диде. Истәлекләр белән мин бик яхшылап танышып чыктым. Аннары, Мөхәммәт ага Гали белән бергәләп, кайчандыр Каюм Насыйриның укучысы булган бер бабайны эзләп киттек. Аны табып, таныштык һәм Каюм Насыйри турында аның белән шактый озак сөйләшеп утырдык. Ул бабай безне буе-сыны, бите-йөзе белән Каюм Насыйрига охшаган икенче бер картка җибәрде. Без ул кешене дә эзләп таптык. Әлеге карт рәсемгә төшәргә риза булмаса да, үзенең кыяфәте белән минем күз алдына килә башлаган Каюм Насыйри образын байтак кына көчәйтте. Шуннан соң мин эшкә керештем. 5–6 вариант ясагач, портретны тотып, Мөхәммәт ага белән теге Каюм Насыйрида укыган бабайга яңадан бардык. Рәсемнәрне күрсәттек. Кайсы вариантның кай ягы белән Каюм Насыйрига якынрак булуын сораштык. Шуннан соң кайтып, мин тагын бер портрет ясадым. Монысын да күрсәттек, картыбыз хуп күрде: «Нәкъ үзе!» — диде. Әйткән фикерен раслатыр өчен булса кирәк, ул бездән рәсемне үзенең элекке сабакташына да күрсәтеп алырга киңәш итте. Без өченче бабайны эзләп таптык. Танышып, хәл-әхвәл сорашканнан соң, аңар соңгы портретны күрсәттек һәм аның кем икәнлеген әйтеп бирүен үтендек. Карт шунда ук: «Бу безне укыткан Каюм хәлфә», — диде.



Б.М.Әлминов



Б.М.Әлминов.
«Каюм Насыйри» портреты.
Автолитография. 1950.

Безгә шул гына кирәк иде дә. Мөхәммәт ага Гали институтның бер утырышында шушы портрет вакыйгасын сөйләп бирде, һәм ул гыйльми советта расланды. Сезнең күз алдыгыздагы рәсем әнә шулай туды». Әлеге портрет 1950 елда язылып бетә. Ул әйләнешкә кереп китә һәм хәзерге вакытта галимнең киң таралыш алган портретларыннан берсе буларак мәгълүм. Шуннан соң да рәссам К.Насыйри портретын берничә вариантта ясый.

Бөтенсоюз («РСФСР өлкәләре, автономияле республикалары һәм союздаш республикалар рәссамнары әсәрләре», 1944) һәм төбәкара («Идел буе рәссамнары әсәрләре», Идел буе шәһәрләрендә, 1943–1945; 1947; 1950; 1953; 1956; 1958) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1944–1945, 1955 елларда Казанда уза. Вафатыннан соң (1980) «7 рәссам истәлегенә» дип аталган төркем күргәзмәсе үткәрелә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Яңа Кырлай авылындагы Габдулла Тукай музей-комплексында, Алабуга шәһәрендәге И.И.Шишкин музей-йортында саклана.

Әд.: Альменов Б. Каюм Насыйриның портреты ничек туды // Совет мәктәбе. 1975. № 3; Әлминов Б.М. // Татар энциклопедиясе: 6 томда. Казан, 2008. 1 т.

И.Х.Хәлиуллин.

ӘМИРХА́Н Фатих (Мөхәммәтфатих) Мөхәммәтзариф улы (01.01.1886, Казан – 09.03.1926, шунда ук), язучы, татар әдәбияты классигы, татар әдәбиятында тәнкыйди реализмга нигез салучыларның берсе.

1895–1905 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый; үзлегеннән рус телен һәм әдәбиятын өйрәнә. 1905–1907 еллардагы революция йогынтысында «әл-Ислах» шәкертләр оешмасы эшчәнлегендә катнаша. 1907 ел башында Мәскәүдә нәшер ителә торган беренче «Тәрбият әл-әтфаль» балалар журналы мөхәррире булып эшли. 1907–1909 елларда «әл-Ислах» газетасы мөхәррире. 1912 елдан «Кояш» газетасы һәм «Аң» журналы белән хезмәттәшлек итә.

Татар әдәбиятына романтик рухта язылган «Гарәфә кич төшемдә» (1907) хикәясе белән килеп керә. Мәгърифәтче әдип буларак, ул татар җәмгыятенең феодаль торгынлыкта яшәвен тәнкыйтьли, милли яңарыш идеалларын яклап чыга. 20 йөз башы татар сатирик әдәбиятының классик әсәренә әверелгән «Фәтхулла хәзрәт» (1909) повестенда искелек тарафдарларын фаш итә. Шул ук елда язылган «Яшьләр» пьесасында татар яшьләренең кадимчелеккә нисбәтле искелектән арыну теләген, шәхес иреген, европача белем алу хокукын яклап чыга, аларның идеалларын һәм омтылышларын тасвирлый. Экзистенциализм һәм экспрессионизм алымнары оста кулланылып язылган «Татар кызы» (1909) хикәясендә татар хатын-кызын ире кулындагы уенчыкка, соңыннан исә «тере мәеткә» әверелүдән, феодаль-патриархаль изелүдән коткару проблемасы күтәрелә. «Хәят» (1911) романтик повестенда балачактан ук рус мәдәниятен күреп үскән татар кызының рухи драмасы тасвирлана. Әсәрдә матурлык эстетикасы, тирән лиризм, табигать һәм мәхәббәт культы өстенлек итә; психологик анализның портретлар, эчке монологлар, пейзажны тасвирлау кебек формалары уңышлы кулланыла. Риваятьләргә нигезләнеп язылган «Ай өстендә Зөһрә кыз», «Сөембикә», «Картада оттырылган Зөлхәбирә», «Бер хәрабәдә» (дүртесе дә — 1913) романтик хикәяләр циклында милли үзаң үзенчәлекләре чагылыш таба. «Тигезсезләр» (1914) психологик драмасында автор сәнгатьчә бай образлар аша дөньяда кешеләрнең тигезсезлеге, мәхәббәтнең яклауга мохтаҗ булуы, кеше бәхетенең нечкәлеге хакында уйлана.



Ф.Әмирхан

1917 елгы Октябрь революциясеннән соң әдип «Кызыл Армия», «Эш», «Татарстан», «Татарстан хәбәрләре»,

«Шәрекъ кызы», «Безнең юл» газеталары һәм журналлары белән хезмәттәшлек итә, республиканың иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында актив катнаша. Шул ук вакытта 1924 елда язылган «Шәфигулла агай» (1991 елда басылып чыга) сатирик хикәясендә эшчеләр сыйныфы вәкилләренең большевиклар идеологиясе тәэсирендә гамьсез роботларга әверелүен, гасырлар буе яшәп килгән милли традицияләрдән һәм гомумкешелек кыйммәтләреннән ваз кичүен күрсәтә.

Каюм Насыйри белән очрашуы хакында мәгълүматлар юк (галимнең вафаты вакытында ул 16 яшьлек үсмер була). «әл-Ислах» газетасының 1908 ел 14 гыйнвар санында басылган «Тел мәсьәләсенә бер караш» мәкаләсендә мәгърифәтче галимнең филология өлкәсендәге эшчәнлеген бәяләп: «Бу мәсьәләләрне тәфсил иткәндә һәрберсе өстендә әллә никадәр куәт сарыф ителергә вә әллә ничә еллар тәфтиш вә тәхкыйккә мохтаҗ булачаклардыр. Бу мәсьәләләрдә эшләүче кешеләр өчен мөтәвәффа Габделкаюм ән-Насыйри җәнабләренең вакытында халкымыз тарафыннан тәкъдир ителә алмаган хезмәтләре бик кыйммәтле материал булачактыр. Ул хезмәтләре өчен аңар бөтен әдәбиятымыз бурычлы икәнне тиз аңласак кирәк», — дип ассызыклый.

Нәкый *Исәнбәт* истәлекләрендә Ф.Әмирханның 1925 елның 15 февралендә Каюм Насыйриның 100 еллыгына нисбәтле җыелышта ТАССР Мәгариф халык комиссариаты карамагындагы *Гыйльми үзәктә* ясаган чыгышы искә алына. Ул әлеге чыгышында, К.Насыйриның Госман *Арсланов* тарафыннан эшләнгән портретына карата мөнәсәбәтен белдереп: «Бу рәсем белән мин мотлак разый түгелмен! Мин Каюм Насыйри китапларын укып үстем. Китабын укыганда аның язучысын да күз алдына китерәсең. Бу рәсем мин күзаллаган галим Каюм Насыйрига бер дә охшамаган» дигән фикер әйтә. Шуннан соң җыелыш президиумы «Каюм Насыйриның яңа рәсемен ясатырга!» дигән карар чыгара.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1957–1958; Әсәрләр: 4 томда. Казан, 1984–1986; Тел мәсьәләсенә бер караш // Әсәрләр: 4 томда. Казан, 1989. 4 т.; Избранное: Рассказы и повести. М., 1975.

Әд.: Нуруллин И.З. Фатих Әмирхан. Казан, 1988; Хисмәтуллин Х. Фатих Әмирхан: Тормышы һәм иҗаты турында кыскача популяр очерк. Казан, 1961; Магдеев М. Фатих Амирхан: Краткий очерк о жизни и творчестве писателя. Казань, 1986; Нуруллин И.З. Прометей из Ново-Татарской слободы. Казань, 1991; Сайганов А. У истоков эстетики реализма: Эстетика Фатиха Амирхана и её место в развитии татарской реалистической литературы. Казань, 1982.

И.Х.Хәлиуллин.

ӘМИРХА́НОВ Рашат Мәхмүт улы (20.05.1939, Үзбәкстан ССРның Бохара шәһәре – 14.12.2000, Казан), татар иҗтимагый фикере белгече, философия фәннәре кандидаты (1982).

Казан университетын тәмамлый (1972). 1965 елдан — Электрофизика институтында: техник, өлкән инженер. 1974 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1993 елдан — иҗтимагый фикер тарихы һәм исламият бүлеге мөдире. 1997 елдан — ТР Фәннәр академиясе Тарих институтында шул ук исемдәге бүлек мөдире. Хезмәтләре татар иҗтимагый фикере тарихына карый. Фәнни эшчәнлеген иҗтимагый фикер һәм ислам белеме чыганакларын бастыруга, татар халкы тарихының моңарчы тикшерелмәгән проблемаларын, шәхеслә-

рен һәм чорларын тирәнтен өйрәнүгә, татар фәлсәфи фикере һәм төбәктә ислам тарихы буенча хезмәтләр әзерләүгә, Татарстанда бүгенге чорда иҗтимагый фикер үсешен һәм аның сәяси, социологик, идеологик аспектларын барлауга багышлый. Каюм Насыйриның күпкырлы фәнни эшчәнлегенә аеруча зур әһәмият бирә. 1975 елның 14 февралендә Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулуга багышланган язмасында мәгърифәтче юбилееның Татарстан җәмәгатьчелеге тарафыннан киң билгеләп үтелүен тәфсилле тасвирлый. Республика музейлары һәм китапханәләрендә, галимнең туган ягында аның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган төрле күргәзмәләр, тантаналы җыелышлар, фәнни конференцияләр үтүне бәян итә. Татар академия театры бинасында К.Насыйри хөрмәтенә багышланган тантаналы җыелышта ТАССР мәдәният министры Ә.С.Миндубаевның, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан университеты, Казан педагогия институты галимнәре, язучылар, мәдәният эшлеклеләре, партия һәм совет хезмәткәрләре, укытучылар катнашында Казан университетының Актлар залында һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы конференц-залында узган конференциядә тарихчылар, тел галимнәре, әдәбиятчылар: А.Н.Кононов, Я.Г.Абдуллин, М.З.Зәкиев, М.В.Гайнетдинов, В.Х.Хаков, К.Ф.Фасиев, М.И.Мәхмүтов, Х.Ш.Мәхмүтов, Л.Т.Мәхмүтова, Ш.С.Ханбикова, Ә.Н.Хәйруллин, С.Х.Акбиев һәм башка галимнәрнең докладлар белән чыгыш ясауларын билгеләп үтә. Аларның материаллары аерым җыентык итеп бастырыла. Юбилей көненә К.Насыйри әсәрләре җыентыгының беренче томы һәм аның «Әнмүзәҗ»е («Татар теле грамматикасы») нәшер ителә.

Хезм.: Общественная и философская мысль в Татарии начала XX в. М., 1990 (автордаш); Татарская социально-философская мысль средневековья (XIII – середина XVI вв.): В 2 кн. Казань, 1993.

Әд.: Амирханов Р.М. Мероприятия, посвящённые 150-летию со дня рождения Каюма Насыри // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Ф.С.Гыйниятуллина.

«ӘНМҮЗӘҖ» (гарәп теленнән — үрнәк, мисал), морфология һәм синтаксис кагыйдәләре турында грамматика китабы. 1895 елда Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм Казан университеты басмаханәсендә 87 бит күләмендә бастырыла.


انموذج

لسانمزنك صرف ونحو قاعدلرى بيانندە بر رسالەدر

تجربه يوزندن اول مرتبه

عبدالقيوم عبدالنصير اوغلى تصنيف قيلمشدر.

قزان

١٣٠٣ ـ

بو كتاب قزان اوڭيورتيسنڭ طبع خانەسندە باصلمشدر

اولنبشدر ل ١٨٩ بحى بابدە.

КАЗАНЬ.

Типо-литография Императорскаго Университета.

1895.

К.Насыйри. «Әнмүзәҗ». Казан, 1895.

Элгәреге авторларның грамматикалары белән чагыштырганда, бу бөтенләй яңача төзелгән лингвистик хезмәт. Анда 19 йөзнең 2 нче яртысына караган татар халык сөйләм теле үрнәкләреннән бай материал тупланган. Структур корылышы ягыннан түбәндәге бүлекләргә аерыла: авазлар һәм исемнәр; фигыльләр; хәрефләр; тәр-

киб вә тәсныйф (сүзләрне бәйләү чаралары).

К.Насыйри әлеге хезмәтендә татар теленең 10 сузык авазын күрсәтә. Алар өчен гарәп графикасы җирлегендә өстәмә билгеләр системасын эшли. Тартык авазлар рус лингвистикасының артикуляцион-акустик терминнарына таянып бүленә. Морфология бүлегендә татар телендә кабул ителгән гарәп терминологиясеннән файдалана. Хезмәттә 800 гә якын фигыль теркәлгән. Исемнәр алты төрле килеш белән төрләндерелә. Сүзтезмәнең дүрт төре күрсәтелә: изафәле, аергычлы сүзтезмәләр, исем җөмлә һәм фигыль җөмлә. Китерелгән мисаллар татар теленең җанлы сөйләмен чагылдыра, табигый булулары белән аерылып тора. Халык авыз иҗаты үрнәкләре дә күп файдаланылган. Гарәп-фарсы лексикасы мул кулланылу — шул заман язма әдәби теленә хас күренеш.

«Әнмүзәҗ фи ән-нәхү» исеме белән 1910 елда бертуган Кәримовлар нашрлегендә кабат бастырыла. Шулай ук кара: *Грамматика*.

Чыг.: Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан, 1895; шул ук. Әнмүзәҗ. Казан, 1975.

Әд.: Баширова И. Каюм Насыйри. Әнмүзәҗ. Казан, 1975 // Советская тюркология. 1975. №3; Рамазанов Ш. Каюм Насыйри — татар әдәби теленә нигез салучы // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Яруллина Л.И. К.Насыйриның «Әнмүзәҗ» хезмәтендә һәм «Ләһҗәи татари» сүзлегендә сузык авазларның язуда бирелеше // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения Каюма Насыри. Казань, 2015.

Р.Ф.Исламов.

ӘСӘДУ́ЛЛИН Абдулла (Габдулла) Шаһи улы (28.11.1926, Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районы Күгеш авылы – 07.05.2004, Казан), педагог, педагогика фәннәре докторы (1992), профессор (1994), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1996), Халык мәгарифе отличнигы.

Ташкент педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1952), Үзбәкстан ССРның Нәманган шәһәрендә урта мәктәптә укытучы булып эшли. 1957–1958 елларда — Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтында методист, 1958–1963 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр. 1963–1991 елларда — РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Татарстан филиалында өлкән фәнни хезмәткәр. 1993 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Тарих институты каршындагы Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгендә әйдәп баручы хезмәткәр. Хезмәтләре башлангыч мәктәптә рус теле укыту методикасының фәнни нигезләренә карый. Рус мәктәпләре өчен татар теле, татар мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре һәм аларны укыту методикасына караган хезмәтләр авторы. Шулай ук күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның татар балаларын рус теленә укыту тәжрибәсен өйрәнә. Бу хакта «Каюм Насыйри рус телен өйрәнү турында» мәкаләсендә бәян итә. Галимнең: «Россиядә яшәгән һәрбер кеше өчен рус телен белү мөһим. Һәрхәлдә ул укый һәм яза белергә тиеш» дигән сүзләрен китерә һәм йөз еллар элек язылган булса да, әлеге фикернең бүгенге көн өчен бик актуаль яңгыравын, К.Насыйриның татар балаларына рус телен укытуның беренче нигез ташын салган шәхес булуын, аның

яшь буынга белем-күнекмәләр биргәндә татар телен беренче чиратта рус мәдәниятенә таянып өйрәтүнең алшартларын билгеләвен, рус телен өйрәнгәндә аерым сүзләрне, авазларның урыннарын, морфология һәм синтаксисны белүне максат итеп куюын, үзенең рус теленә караган уку-укыту һәм методик әсбапларында татар балаларын рус теленә өйрәтү буенча квалификацияле методик киңәшләр бирүен, аларның 70 нче елларда да гамәли әһәмиятен югалтмавын, мәгърифәтче галимнең шул юнәлештә бай мирас калдыруын ассызыклый.



А.Ш.Әсәдуллин

К.Д.Ушинский, «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәте өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри // Совет мәктәбе. 1965. № 2; Первоначальное обучение русскому языку в татарской школе. Казань, 1978; Обучение связной русской речи в начальных классах татарской школы. Казань, 1985; Татарский язык в русскоязычной аудитории. Казань, 1995 (автордаш); Татарская речь = Татар сөйләме (для учителей, работающих с русскоязычными учащимися). 9 класс. Казань, 2001.

Әд.: Асадуллин А.Ш. Каюм Насыри об изучении русского языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Ф.С.Гыйниятуллина.

«ӘСӘРЛӘР», Каюм Насыйриның төрле өлкәгә караган хезмәтләре җыентыгы. 1971 елда Казанда бастырыла. Ул СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан 1956 елда Татарстан китап нәшриятында бастырып чыгарылган «Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр» бер томлыгы нигезендә төзелә. Текстлар бераз кыскартылып, теле берникадәр җиңелләштереп бирелә.

Матур әдәбият әсәрләреннән «*Әбугалисина кыйссасы*», «*Кырык вәзир кыйссасы*», «*Әфсанәи Гөлрох вә Камәржән*», «*Кырык бакча*»; «*Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият*», тарих белән бәйле «Пугачау кыйссасы», «Зөя каласы»,



К.Насыйри. «Әсәрләр». Казан, 1971.

тел һәм әдәбият белеменә караган «Әлхитабес-салис», «*Кабуснамә*» хезмәтләре урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956; шул ук. Әсәрләр. Казан, 1971.

Р.Ф.Исламов.

«ӘФСАНӘЙ ГӨЛРӨ́Х ВӘ КАМӘРЖӘ́Н», фантастика алымы белән язылган проза әсәре. Ул, госманлы төрекләрендә булган бер варианттан Каюм Насыйри тарафыннан үзгәртелеп, татар халкы теленә яраклаштырылган. Әсәрнең жанрын К.Насыйри үзе «роман» дип атаган. Әдә-

бият галиме Мөхәммәт *Гали* билгеләп үткәнчә, автор аны «өч кисәк итеп бастырырга уйлаган булган. Ләкин үзе исән вакытта тик бер кисәген генә бастырган. Калган өлешенең тәржемә ителеп-ителмәве дә мәгълүм түгел».

Әчтәлегендә Чин (Кытай) падишаһы Шөҗаг шаһның кызы Гөлрох белән Исфаһан (Иран) патшасы Харәзем шаһның угылы Камәрҗанның мажаралары, аларның улы Асыл һәм Басра падишаһы Ходаколның кызы Фәррахбану белән Камәрҗанның улы Насылның мажаралары турында бәян ителә.

Күләме 54 биттән гыйбарәт бу әсәр беренче тапкыр 1896 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә. К.Насыйриның 1945, 1953, 1956, 1974 (2 том), 2005 (3 том) елларда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»енә, 1971 елда басылган «Әсәрләр»енә кертелә.


Чыг.: Насыйри К. Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан. Казан, 1896.

Әд.: Гали М. «Әфсанәи Гөлрөх вә Камәрҗан» турында // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; Катанов Н. «Афсанэ-и Гюлрух ве Камарджан» («История Гюльрух и Камарджана»). Казань, 1896. Тип. ун-та. 54 стр. // Деятель. 1897. № 4.

Р.Ф.Исламов.

«ӘХЛА́К РИСАЛӘСЕ́», балалар өчен проза әсәре. Каюм Насыйри тарафыннан балаларга киңәш бирү рәвешендә языла. Китап беренче тапкыр 1881 елда Казан университеты басмаханәсендә 32 бит күләмендә нәшер ителә.

Әсәрнең эчтәлеге балаларны гыйлем өйрәнергә, надан калмаска, үз-үзеңне башкалар алдында әдәпле тотарга һәм башка шундый уңай сыйфатларга өндәүдән гыйбарәт. Аның «Гыйлем вә наданлык» дип аталган беренче өлешендә К.Насыйри балаларга болай дип мөрәҗәгать итә: «Әй газиз бала, Агаһ [хәбәрдар] бул, адәмгә иң әүвәл бигрәк кирәк вә бигрәк лазем [тиешле] нәрсә — гыйлемдер, вә гыйлем дигәнемез белмәгән нәрсәне үгрәнеп вә сорашып белмәктер. Вә наданлык дигәнемез белмәклеге лазем булган нәрсәне белмәссезлектер. Бу наданлык кешене игътибардан чыгара торган нәрсәдер, вә хайван сыйфатына кертә торган сыйфаттыр, кайда барса да, надан кешенең кадере юктыр. Надан кала күрмә, сабак укыганда белмәгән вә аңламаган сүзеңне хәлфәңнән сора».


اَخْلَاق رِسَالَه‌سی

«بالاارغه» یاوز خلقدان صافلاتوب ایدگو خلق یلان
خلقلاشق اوچون
آتا آنا نصیحتی منزلتنده
بر نصیحتدر
عبدالقیوم ملاعبدالناصر اوغلی تنك اجتهادائزندن بالاارغه
اهلای تعلیم اوچون
بر طریقت در
۱۲۹۸ سنه‌سنده
بوکتاب‌نك باصمه‌سنه رخصت بیرلدی پیش‌بورخان
۲۳ نجی مارت ۱۸۸۱ نجی یلنك ...
بوکتاب قزان اوتیو بر بستیتی‌نك طبع خانه‌سنده باصمه
اولنمشدر اوّل مرتبه ۱۸۸۱ نجی یلنك

К.Насыйри. «Әхлак рисаләсе». Казан, 1881.

Китап кабат 1884, 1890, 1893, 1898, 1901, 1904 елларда (соңгы икесе китапчы Исмәгыйль Шәмсетдинов иганәсендә) — университет, 1913 елда «Сабах» ширкәте тарафыннан «Өмид» басмаханәләрендә дөнья күрә. Әсәрнең бик кыска бер өлеше К.Насыйриның 1953, 1956, 1974 (2 том), 2005 (3 том) елларда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр»енә кертелә.


Чыг.: Насыйри К. Әхлак рисаләсе. Казан, 1881.

Әд.: Вазеева Ж. Каюм Насыйри һәм балалар әдәбияты // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Катанов Н.Ф. «Ахляк рисалесы» («О нравственности») // Деятель. 1898. № 5.

Р.Ф.Исламов.

ӘХМӘДИ́ЕВ Шәһит Гыймадетдин улы (29.12.1888, Казан губернасының Чистай өязе Татар Ялтаны авылы – 12.08.1930, Казан), сәясәт эшлеклесе, язучы, журналист, укытучы.

1901–1907 елларда «Хөсәения» (Оренбург шәһәре) һәм «Галия» (Уфа шәһәре) мәдрәсәләрендә белем ала, шәкертләр хәрәкәтендә катнашкан өчен, икесеннән дә куыла. 1908–1909 елларда Тобол губернасында балалар укыта. 1917 елда — Казанда Татар приказчиклары җәмгыятен оештыручыларның берсе, «Аваз» газетасы мөхәррире. 1908 елдан — эсер-максималистлар, 1917 елдан большевиклар тарафдары. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче корылтаенда катнаша (1917). Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–1918), туфракчылар фракциясе әгъзасы. 1918–1919 елларда — Казан губернасы халык мәгарифе комиссары, «Эш» газетасы мөхәррире, Эчке Россия мөселманнарының мәгариф эшләре комиссары урынбасары, бер үк вакытта Казан губернасы Гадәттән тыш комиссиясе әгъзасы, «Кызыл Армия» газетасы мөхәррире; Галимҗан Ибраһимов белән бергә «Мәгариф» журналын оештыручыларның берсе. 1920–1921 елларда — Төркестан АССРда: «Кызыл Шәрекъ» газетасы мөхәррире, халык мәгарифе комиссары, Төркестан АССР



Ш.Г.Әхмәдиев

Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы.

1921 елның көзендә Казанга кайта, Идел-Урал буендагы ачлык вакытында халыкка ярдәм оештыруда катнаша. 1922–1924 елларда — Профессиональ союзларның Татарстан советында мәдәният бүлеге мөдире. 1924–1926 елларда — ТАССР мәгариф халык комиссары. 1925–1927 елларда — СССР Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы.

1910 елдан Казанда әдәбият өлкәсендә эшчәнлек алып бара. 1917–1921 елларда басылган хикәяләре татар хезмәт ияләренең авыр тормышын, татар хатын-кызларының ирексез хәлен күрсәтүгә багышланган; әкиятләрендә дуслыкка, табигать матурлыгына дан җырлана. Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев әсәрләренә, «Сәйяр» һәм «Нур» театр труппалары эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр авторы.

ТАССР мәгариф халык комиссары Ш.Әхмәдиев, *Гыйльми үзәкне* оештыручыларның берсе буларак, шул оешмада К.Насыйриның тууына 100 ел тулуга багышланган җыелышта (1925) ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Ш.Ш.Шәймәрданов һәм Халык Комиссарлары Советы рәисе Х.З.*Габидуллин* хатын укый. Әлеге хатта: «Йөз еллыгы уңае белән бәйрәм ителгән Каюм бабабыз үзенең гыйльми-әдәби хезмәтләре белән татар тарихының менә шундый кадерле эшчеләренең берсе, бәлки, беренчесе. Шуңа күрә дә Татарстан җөмһүрияте хөкүмәте ул өлкән бабаның тууына 100 ел тулган көнне олылап үткәрүне тиешле санады һәм башка берничә төрле сагынмалык-ядкяр эш-

ләү белән бергә аның әсәрләреннән, һич булмаса, кайберләрен бастыру, аның тормышы, хезмәте турында тулы материал, мәгълүмат бирерлек мәҗмуга чыгарту чараларын күрәчәк», — диелә.

Әсәр.: Шәһит Әхмәдиев әсәрләре. Казан, 1930; Сайланма әсәрләр. Казан, 1959.

Әд.: Сабиров С. Кайнар йөрәкле көрәшче // Казан утлары. 1968. № 12; шул ук. Ахмадиев Ш.Г. // Борцы за счастье народное. Казань, 1983. Кн. 2; Общественно-политический деятель Ш.Ахмадиев. Казань, 1988.

Ф.Г.Кәлимуллина.

ӘХМӘДУ́ЛЛИН Азат Гыйльмулла улы (13.10.1932, Татарстанның Саба районы Байлар Сабасы авылы – 08.12.2021, Казан), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1994), Язучылар берлеге әгъзасы (1974), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1982), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2002). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1999).

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1956), Тобол педагогия институтында укыта. 1958–1961 елларда Татарстан радиокомитетында эшли. 1963–1981 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1972 елдан — директор урынбасары. 1981 елдан — Казан университетында: 1988 елдан — профессор, 1999 елга кадәр — татар әдәбияты кафедрасы мөдире. Бер үк вакытта, 1999–2004 елларда, Казан педагогия университетында, 2000 елдан — татар әдәбияты кафедрасы мөдире.

Төп хезмәтләре татар драматургиясенең барлыкка килү һәм үсеш тарихын гыйльми күзаллауга багышлана, татар театры тарихына, сәхнә сәнгате



А.Г.Әхмәдуллин

үзенчәлекләренә, Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Тажи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат, Хәй Вахит, Туфан Миңнуллин һәм башка татар язучылары, драматурглары иҗатларына карый. Урта мәктәп өчен әдәбият дәреслекләре (1970 елдан бирле 15 басма чыга), тәнкыйть мәкаләләре җыентыклары авторы. Әдәби терминнар тупланган «Әдәбият белеме сүзлеге»н (1990) төзүче.

«В.И.Ленинның 100 еллыгы», «Хезмәт ветераны» медальләре, ТАССР Югары Советы Президиумы Мактау грамотасы, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Хезм.: Ничек сурәтләргә сине, заман-даш? (Бүгенге татар драматургиясенең актуаль проблемалары турында). Казан, 1976; Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Казан, 1980; Офыклар киңәйгәндә. Казан, 2002; Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе. Казан, 2007; Татарская драматургия. Казань, 2012.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ӘХМӘ́РОВ Шаһбазгәрәй Измаил (Исмәгыйль) улы (12.03.1853, Казан – 01.04.1900, шунда ук), педагог, җәмәгать эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1898). Морзалар нәселеннән.

Казанда Икенче ир балалар гимназиясен (1874), Казан университетын (1878) тәмамлый. 1876–1900 елларда — *Казан татар укытучылар мәктәбендә* педагогика, рус теле һәм

әдәбияты укытучысы, 1881 елдан (М.Мәхмүдов пенсиягә киткәннән соң) — шунда ук инспектор (директор). Әлеге уку йортындагы эшчәнлегенең башлангыч чорында күп кенә күренекле зыялылар, галимнәр, шул исәптән шунда ук мөгаллим булып эшләгән Каюм Насыйри белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыра. Шагыйрь, тәрҗемәче, Шәрекъ телләре белгече Галимҗан *Акчуринның* «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат» хатирәсендә В.В.*Радловның* аны, Каюм Насыйрины һәм Ибраһим *Терегуловны* Казан татар укытучылар мәктәбенә укыту эшенә чакыруы, аларның 7–8 ел үзара аралашуы хакында искә алына (кара: *Истәлекләр*). Бер үк вакытта, 1896 елдан, — Казан шәһәр думасы гласные, 1898 елдан — Казан мөселман хәйрия җәмгыяте рәисе.



Ш.И.Әхмәров

Яхшы методист була, шәкертләрне рус грамотасына өйрәтүнең эзлекле тәртибен булдыру өчен берничә уку ярдәмлеге (мәсәлән, «Грамматика русского языка для татар», 1889) яза. «Казан-татар теле шивәсендә фигыльне синтаксик яктан тикшерү» уку әсбабы (1895) авторы. Шәһәр училищесы укытучысы М.Иманаев белән берлектә рус-татар училищелары өчен «Рус теле» («Русское слово», 1895) дәреслеген төзи. Дәреслек күп тапкырлар нәшер ителә һәм 1924 елга кадәр файдаланыла. Татар мәктәбенең дөньяви характерда булуы һәм рус теленең Идел буе халыклары арасында мәдәни багланышлар чарасы буларак таралуы тарафдары була.

Хезм.: Синтаксический разбор глагола в казанско-татарском наречии. Казань, 1895; Казанское мусульманство // Городской и сельский учитель. 1897. №3.

Әд.: Акчурин *Г.* Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Исламов Р.Ф. Казан, 2017; Бадрутдинова М.Ш., Галимуллина Г.Х. Шагбаз-Гирей Ахмеров и его семья // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: сборник статей итоговой научно-практической конференции. Казань, 2012; Галимуллина Г.Х. Анализ статьи Х.З.Багаутдиновой о проекте Ш.И.Ахмерова по изданию еженедельной газеты «Казань» // Актуальные проблемы регионоведения и науковедения: Сборник статей научной конференции. Казань, 2023.

И.Х.Хәлиуллин.

ӘХМӘТГАЛИ́ЕВА (Янбаева) Ялкын Сафа кызы (02.02.1934, Ленинград), төрки телләр белгече, филология фәннәре кандидаты (1978), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Гатаулла *Баязитовның* улы Оренбург Дини Мөхәммәди җыены мөфтие Мөхәммәтсафа оныгы.

Ленинград университетының Шәрекъ телләре факультетын тәмамлый (1957). 1969–1989 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли.

Хезмәтләре татар әдәби теле тарихын, урта гасырлар төрки язма чыганаклары телен өйрәнүгә карый. «Төрки телле язма ядкәр — «Кисекбаш китабы»н өйрәнү» («Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы»», 1979) хезмәтендә дастанга гомуми сыйфатлама бирә, сюжет тарихын яктырта, әсәрнең жанрын билгели, фонетик, морфологик

һәм лексик үзенчәлекләрен тикшерә. «Дәфтәре Чыңгызнамә» язма истәлегенең морфологик хосусиятләрен тасвирлый, фольклор әсәрләренә хас аңлаешлы, җиңел тел белән язылуын билгеләп үтә. «Каюм Насыйри һәм татар грамматикасы» фәнни мәкаләсендә Каюм Насыйриның грамматика өлкәсендәге тикшеренүләренә, аерым алганда, «*Әнмүзәҗ*» хезмәтенә анализ ясый, галимнең бу өлкәдәге эшчәнлегенә бәя бирә. Хезмәттә рус һәм гарәп лингвистика мәктәпләре йогынтысының ачык чагылуын күрсәтә. Аның чордашлары һәм каләмдәшләре Гали Мәхмүдов, Александр Троянский, Иосиф Гигановның тел белеменә караган хезмәтләре белән чагыштыра. Галимнең, тел үзенчәлекләреннән чыгып, татар теленең төп грамматикасын төзүгә ирешүен, лингвист буларак, үз чорының хәзерге татар тел белеме үсешенә башлангыч биргән алдынгы карашларына таянуын искәртә. «Әнмүзәҗ» хезмәтендә татар теле грамматикасын өйрәнүдә кулланылган алымнарны Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Габдрахман Сәгъди, Мөхетдин Корбангалиев, Фатыйх Сәйфи һ.б.ның да үз хезмәтләрендә файдалануларын ассызыклый. «Татар мәгърифәтче галиме Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни конференция» мәкаләсендә (1975) 20 дән артык докладка кыскача тасвирлама бирә, К.Насыйриның күпкырлы эшчәнлеген өйрәнүдә галимнәрнең зур тырышлык куюларын, бу юнәлештә биниһая эшләр башкаруларын, аның хезмәтләренең бүгенге көндә дә фәнни кыйммәте югалмавын искәртә. Ленинградта яшәү чорында Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш теллəр институты филиалы китапханәсендә сакланучы иске татар китаплары коллекциясен барлый һәм 1802–1931 елларда басылып чыккан 4000 китапны системалаштыра, нәтиҗәдә, «Россия Фәннәр академиясендә иске татар китаплары каталогы» (2010) хезмәте дөнья күрә. Биография бүлегендә К.Насыйри «Әбугалисина»сының тәрҗемәсе, татар теле тупланмаларында «Әнмүзәҗ» грамматикасы саклануын билгеләп үтә. Бабалары рухына багышлап, «Баязитовлар нәселе» (2009) китабын яза. Фәнни эшчәнлегенең тагын бер юнәлеше — Кырым ярымутравындагы җирле халыкның зур булмаган этник төркеме — кырымчакларның тарихын, телен өйрәнү: беренче «Кырымчак-инглиз-рус сүзлеге» (2012) төзеп бастыра; Марсель Перич шигырьләрен, библия текстларын кырымчаклар теленә тәрҗемә итә. Стокгольмда (Швеция) гарәп графикасында нәшер ителгән «Хәбәрче» журналын тикшереп, татарларга багышланган язмалар турында мәгълүмат бирә, басманың стиленә туктала, эчтәлеген анализлый.

1993 еллардан Иерусалим шәһәрендә (Израиль) яши.

Хезм.: Научная конференция, посвященная 150-летию со дня рождения татарского ученого-просветителя Каюма Насыри // Советская тюркология. 1975. № 3; Каюм Насыри и татарская грамматика // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Архив Р.Фахрутдинова в Ленинградском отделении Института востоковедения АН СССР // Исследования по лексике и грамматике татарского языка. Казань, 1986; Потомки Баязитова. Казань 2009; Каталог старотатарских книг в Российской Академии наук = Catalogue of the old Tatar books in the Russian academy of sciences: (1802–1931) Jerusalem, 2010.

Әд.: Бәширова И.Б. «Хәбәрче» журналы турында // Фәнни Татарстан. 2021. № 2.

Ф.Г.Камальтдинова.

Б

БАЕМБИ́ТОВ (Баембәтов) Гыйлемдар Солтан улы (сентябрь, 1886, Уфа губернасының Бәләбәй өязе Чакмагыш авылы – 21.08.1933, Мәскәү), сәясәт эшлеклесе, язучы, журналист.

Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, Казанга килеп, Татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Әсерлар сәяси түгәрәкләрендә катнашкан өчен, әлеге уку йортыннан куыла. 1905 елның октябрь-ноябрендә Казанда беренче яшерен татар басмаларыннан «Хөррият» газетасын нәшер итүдә катнаша. 1906 елның 6 апрелендә Казанда кулга алына. 1907 елда Уфа шәһәрендә яшерен басмаханә оештыра, анда революцион брошюралар бастыра. 1905–1918 елларда эсерлар партиясендә тора, 1917–1918 елларда — татар-башкорт сул эсерлар оешмасы җитәкчеләренең берсе. Революцион эшчәнлеге өчен берничә тапкыр кулга алына, 1909–1912 елларда Вологда губернасында сөргендә яши. 1915 елда Уфада мөселман кулланучылар җәмгыятен оештыра. 1917–1918 елларда «Ирек» газетасында хезмәттәшлек итә, төрки-татарларга территориаль мохтарият бирүне яклый; Уфа шәһәр думасы һәм идарәсе әгъзасы, «Көрәш» газетасы мөхәррире, Уфа Халык Хуҗалыгы Советы рәисе урынбасары, Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–1918), «туфракчылар» фракциясе әгъзасы.

Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армия сафларында: чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык армиясенә каршы сугышларда катнаша; «Кызыл яу» газетасы мөхәррире, Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе сәяси бүлегенең мөселман бүлекчәсе җитәкчесе. Көнчыгыш фронтның коммунист-мөселманнар конференциясендә РКП(б)ның Көнчыгыш фронттагы татар-башкорт үзәк бюросы рәисе итеп сайлана (Сызрань шәһәре, 1919). 1919–1920 елларда — Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлек башлыгы, Казан губерна башкарма комитеты һәм РКП(б) губерна комитетының мөселманнар бюросы әгъзасы. 1920–1921 елларда — Казан хәрби-сәяси агитация курслары мөдире. 1922 елда — Мәскәүдә: Шәрекъ халыкларының коммунистик университеты лекторы, ВЦСПС инструкторы. 1922 ел ахырыннан — Урта Азиядә: Бохара Үзәк Башкарма Комитеты һәм Бохара мәгариф нәзарәте (халык комиссариаты) коллегиясе әгъзасы, РКП(б)ның Урта Азия Үзәк Комитеты каршындагы Ташкент Көнчыгыш матбугаты бюросы мөдире, Профсоюзларның Гомумбохара советы мәдәният бүлеге мөдире һәм «Хасабе сәхифәсе» («Хезмәт сәхифәсе») газетасы мөхәррире. 1924–1925 елларда — Мәскәүдә Шәрекъ халыкларының үзәк нәшрияты хезмәткәре, 1925–1927 елларда — Башкортстан АССРда ВКП(б)ның Яңавыл волость комитеты секретаре, 1928–1929 елларда — Мәскәүдә Баш сәнгать идарәсе инс-

пекторы, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы яңа төрки (латин) алфавиты комитеты инструкторы.



Г.С.Баембитов

1905–1907 еллардагы революция һәм 1917 елгы Февраль революциясе турында пьесалар, татар телендә «Сәяси экономия» һәм «Тарихи материализм» (1921) уку ярдәмлекләре авторы. В.И.Ленинның кайбер әсәрләрен, Э.Л.Войничның «Овод» («Кигәвен») романын татар теленә тәрҗемә итә. Каюм Насыйри турында истәлекләр яза. Аның мәгърифәтченең 100 еллык юбилеена багышланган «Мәскәүдә Насыйри кичәсе» мәкаләсе «Эшче» газетасының 1925 ел 18 февраль санында дөнья күрә, аннан соң мәкалә «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга» (1926) җыентыгында бастырыла. Анда автор, мәгърифәтченең шул заман сәяси мохите кысаларында язган һәм төрле өлкәләргә караган башка хезмәтләреннән хәзерге заман яшәеше өчен кирәк булганнарын алып, марксизм, пролетариат таләпләре нигезендә эшкәртеп, халыкка җиткерү турында сүз алып бара.

Авыру сәбәпле, 1930 елдан беркайда да эшләми. 1932 елның 21 декабрендә кулга алына, 1933 елның 28 маенда ТАССР бүлегенең ОГПУ коллегиясе тарфыннан «сул эсерларның «Крестьян иттифагы» фиркасен яклау»да гаепләнеп, үлем җәзасына хөкем ителә. 1933 елның 21 августында Мәскәүдә атып үтерелә. 1989 елда аклана.

Әсәр.: Асылган. Казан, 1924; Патша төшерәләр. М., 1924; Каюм Насыйрига 100 ел тулу белән (1825–1925) // Эшче. 1925. 25 февраль; Мәскәүдә Насыйри кичәсе // Эшче. 1925. 18 февраль.

Әд.: Низамов И. Баимбетов Г.С. // Возвращённые имена: Документальные очерки. Казань, 1990.

Ф.Г.Камальтдинова.

БАЛАЛА́Р ӘДӘБИЯТЫ́, гомуми әдәбиятның балаларга багышланган тармагы. Үзенчәлеге — баланың хис-кичерешләре олы кеше тарафыннан сурәтләнү. Шуңа күрә балалар өчен иҗат итүче автор тормыш вакыйгаларын балаларча кичерә, аларча күзаллый һәм уйлый, яшәешне балалар теленә күчерә белергә тиеш.

Татар әдәбиятында 19 йөзнең 1 нче ярты сына кадәр балалар өчен язылган һәм нәшер ителгән әсәрләрнең күпчелеген үгет-нәсихәткә корылган дини эчтәлекле китаплар алып тора: «Кисекбаш» (1845), «Бәдәвам» (1846), «Рисаләи Газизә» (1847), «Ахырзаман китабы» (1847) һ.б. 1859 елда Салихҗан Кукляшевның эчтәлеге белән дини китаплардан аерылып торган «Диване хикәйәте татар» (1859) хезмәте дөнья күрә. Мәктәпләрдә дәреслек буларак та кулланылган әлеге басмадагы халык иҗаты үрнәкләре балалар өчен кызыклы була. «Хуҗа Насретдин» (1845) китабы да балалар тарафыннан яратып укыла.

Каюм Насыйриның Казан басмаханәләрендә нәшер ителгән китаплары дөньяви эчтәлекле татар балалар әдәбиятының формалашуында һәм үсешендә зур роль уйный. Эшчәнлегенең беренче елларында ук мәгърифәтче галим аңлаешлы әдәби телдә язылган балалар әдәбиятының бик ярлы булуын искәрә һәм аны үстерүгә зур көч куя. Аның балалар өчен махсус язылган беренче «*Буш вакыт*» китабы 1860 елда дөнья күрә. Җамал *Вәзиева*: «1860 елда басылып чыккан «Буш вакыт» исемле әсәр татар телендә, бер яктан,

фәнни-популяр әсәрләрнең берсе булса, икенчедән балалар өчен язылган, укырга күңелле итеп төзелгән фәнни-әдәби әсәрләрнең башлангычы булып тора», — ди. «Буш вакыт» — балаларга, гомумән, яшь буынга фәнни мәгълүмат, табигать күренешләре турында белем бирү максатында җанлы татар сөйләменә якын телдә язылган, укыр өчен кызыклы фәнни-популяр басма. Исемендә үк хикмәт бар. Биредә К.Насыйри, балалар сабактан, көндәлек эшләрдән бушаган вакытларын файда белән үткәрсеннәр өчен, кечкенә хикәяләр тәкъдим итә. Рус әдипләренең, башлыча рус педагогы Константин Ушинскийның балаларга атап язылган хезмәтләренә таянып, табигать күренешләрен аңлата. Әлеге китабында автор анатомия, минералогия, табигать күренешләре турында фәнни-әдәби мәгълүмат бирә. Китапның 1909 елгы беркадәр гадиләштерелгән телдәге басмасында «Нашидән бер-ике сүз» дигән кереш мәкаләсендә: «Тәрбиятел-әтфаль фәненә маһир галимнәр балаларның зиһеннәрен ачу, мәгълүматларны күбәйтү өчен төрлечә юллар күрсәтәләр. Болар арасында иң мәкъбуль күрелгән [кабул ителгән] тарикълардан [юлларның] берсе сабактан бушаган заманнарда баланың кулында бик җиңел тел илә ачык итеп язылган китаплар булдырудыр. Фәнгә яки әдәбиятка даир [караган] бик асат тел илә язылган китапларны уку һәм аңлауда бала һичвакыт мөгаллимгә мохтаҗ булмый. Әгәр китаплар бала ялыкмаслык рәвештә кыска һәм кызыклы нәрсәләрдән гыйбарәт булса, үз-үзлегеннән бик күп мәгълүматы артып, зиһене ачыладыр. Ләкин балага биреләчәк китапларның балалар өчен махсус язылган булуына дикъкать кылынырга тиешледер. Баланың кулына зиһене җитмәслек агыр язылган китаплар керсә, ул вакыт укудан тәмам гайрәте чигәдер», — диелә. Бу юлларда наширләрнең балалар әдәбиятына булган таләпләре генә күрсәтелеп калмый, язучының эшчәнлегенә дә тиешле бәя бирелә.

К.Насыйри шулай ук Шәрекъ халыклары әдәбияты әкиятләрен һәм әсәрләрен файдалану аша да татар балалар әдәбиятын баета. «*Кырык вәзир кыйссасы*» (1868–1910 елларда 8 тапкыр басыла), «*Әбугалисина кыйссасы*» (1881–1908 елларда 8 тапкыр басыла), «*Әфсанәи Гөлрох вә Камәржан*» (1896) китаплары балаларда матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияли. 1879–1884 елларда К.Насыйри татар әдәбияты тарихында зур роль уйнаган «*Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият*» китабы өстендә эшли. Ул зурлар өчен язылса да, анда балалар кызыксынып укырлык урыннар да бар. Габдулла *Тукай* үзенең «Исемдә калганнар» әсәрендә 7–8 яшьлек вакытларын искә төшереп: «Кич белән китаплар актарганда, кулыма «Фәвакиһел җөләса» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм», — дип яза.

К.Насыйри балалар күңеленә әхлак орлыклары салучы тәрбия китаплары да, фәнни-популяр һәм матур әдәбият әсәрләре дә иҗат итә. «Җәваһирел-хикәят» (1884) китабында балалар өчен кызыклы хикәяләр, мәзәкләр һәм мәсәлләр урын ала. Биредә вакыйгалар, балалар тормышыннан алынып, аларның хис-тойгылары аша тасвирлана. Соңрак андагы мәсәлләр («Авызына сөяк капкан эт», «Казлар һәм бака», «Ләк-ләк белән чыпчык» һ.б.) дәреслекләргә кертелә, тәрбия чарасы буларак файдаланыла башлый. Мәгърифәтче галим, үзенең дәреслек-кулланмаларын төзегәндә, балаларның яшь үзенчәлекләрен, холык-фигыльләрен исәпкә алып эш итә. «Хисаплык» дәреслегендә (1873) мәсь-

әләләр кызыклы, мавыктыргыч итеп төзелгәннәр, ирексездән аларны чишү теләге туа. Автор мәсьәләләрне, оригиналь чаралар кулланып, фәнни төгәллек белән балаларга аңлаешлы телдә төзи. Н.Ф.*Катанов* аның «яшь татар балаларының аңын үстерү өчен» татар педагогикасында аерым игътибарга лаек хезмәт булуын билгеләп үтә. Галимнең халык авыз иҗатына (мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар) караган хезмәтләре дә баланы барлык яктан үрнәк булырлык шәхес итеп тәрбияләргә ярдәм итә. Халык арасыннан җыйган әкиятләре («Үги кыз», «Байдек», «Гөлнәзек», «Өч туган», «Төлке белән дуслык тотучы аю», «Мәче белән аю» һ.б.) татар фольклористика белемен үстерү белән беррәттән балалар әдәбияты фондын тулыландыруга да зур өлеш кертә, балалар китабына куйган таләпләре, үрнәкләре татар балалар әдәбиятын үстерүгә нигез булып тора.

Күп кенә татар галимнәре (Ж.Вәзиева, Н.Юзиев, Ф.Яхин һ.б.) үзләренең хезмәтләрендә К.Насыйрины татар балалар әдәбиятын башлап җибәрүче дип билгеләп үтәләр. Ф.Яхин: «*„Буш вакыт“* безнең яңа, ягъни җәдиди әдәбиятыбызның балалар өчен язылган тәүге әдәби әсәре дә түгелме? Чын мәгънәсендәге балалар әдәбияты Европада Шарль Перроның (1628–1703) халык иҗатыннан алынган әкиятләреннән (1697 елдан) башланып киткән кебек, бездә ул К.Насыйриның «Буш вакыт»ыннан (1860 елдан) беренче адымнарын ясамыймы? Әлбәттә! Балалар җәдитчелек матур әдәбияты бездә шулай киң кырлы, тирән эчтәлекле, мәдәни-мәгънәви юнәлеш алып башланып китә», — дип яза.

К.Насыйриның балалар әдәбияты өлкәсенә караган хезмәтләре нигезендә белемле, сәламәт, җәмгыятькә файдалы шәхес тәрбияләү ята.

Әд.: Әдәби сүз хакы. Казан, 2020; Вазеева Ж. Каюм Насыйри һәм балалар әдәбияты // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Габдулла Тукай. Энциклопедия. Казан, 2016; Насыйри К. Буш вакытларда укырга сүзләр. Казан, 1867; Насыри К. Избранные произведения. Перевод с татарского языка. Казань, 1977.

Ф.Г.Камальтдинова.

БАТТА́Л Габделбари Габдулла улы (08.12.1880, Самара губернасының Бозаулык өязе Яңа Белогор авылы – 26.04.1969, Истанбул шәһәре, Төркия), тарихчы, филолог, журналист, тәрҗемәче һәм укытучы, татар милли-азатлык хәрәкәтендә катнашучы; төрек җәмәгать эшлеклесе. Төркиядә яшәгәндә (1925–1969) Abdullah Battal-Taymas (Абдулла Баттал-Таймас) буларак таныла.

Оренбургтагы «Кәрвансарай», Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәләрендә белем ала. 1904 елда укуын дәвам иттерү теләге белән Каһирәгә (Мисыр) бара, анда 1908 елга кадәр гарәп теленнән белемен камилләштерә, гарәпчә нәшер ителүче «әл-Мөкаддәм», «Җәридә» газеталары, «әл-Мәнар» журналы белән хезмәттәшлек итә. Россиягә кайткач, 1908–1910 елларда «Вакыт» газетасында (Оренбург шәһәре) эшли, гарәп теленнән әдәби, иҗтимагый-фәлсәфи китапларны тәрҗемә итеп бастыра. 1911–1912 елларда Троицк шәһәре мәдрәсәсендә укыта. Әхмәтһади *Максуди* чакыруы буенча Казанга килә, 1913–1917 елларда «Йолдыз» газетасында сәркатип булып эшли. Бер үк вакытта «Мәктәп», «Ак юл», «Шура», «Сөембикә» журналлары белән хезмәттәшлек итә.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң бер төркем фикердәшләре белән милли азатлыкка өндәгән «Ко-

рылтай» (1917–1918, март), ул ябылгач, «Алтай» (1918, апрель-май) газеталарын нәшер итүдә, Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары эшендә актив катнаша. Казаннан сайланган Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–1918). 1918 елның 2 нче ярты сында бер төркем Милли Идарә вәкилләре (Ибнеәмин Әхтәмов, Гаяз Исхакый, Гомәр Терегулов һ.б.) белән «кызыллардан» качып Себергә китә, Кызылъяр шәһәрендә Фоат Туктаров белән «Маяк» газетасын чыгара. 1919–1920 уку елында Томск педагогия курсларында укыта. Анда Заһид Нуркин белән бергә «Уку китабы» дәреслеген нәшер итә. 1920 елның мартында Казанга туганнары янына кайта, кулга алына һәм революцион хөкемгә тартыла, җәй башында хезмәт белән тәрбияләү лагерена җибәрелә. Шул елның августында аннан кача, Баку, Казан, Мәскәү, Петроград шәһәрләрендә ялган документлар белән яши. 1921 елның җәендә яшерен рәвештә Финляндиягә китә. Анда 3 елдан артыграк укыта, үзлегеннән фин, француз телләрен өйрәнә, Төркия, Германия матбугат чаралары белән хезмәттәшлек итә. «Казан төркиләре» дип аталган тарихи хезмәтен яза башлый. 1925 елның ноябреннән — Төркиядә: Әнкарада Төрек филологиясе институтында, 1927 елдан Матбугат мөдирлегендә (соңрак ул Тышкы эшләр министрлыгына карый) рус теленнән төрекчәгә тәрҗемәче булып эшли. 1932 елда Истанбулда үткәрелгән Беренче төрки телләр корылтаенда катнаша. 1947 елда төп эшеннән китә һәм Истанбулга күченә.

Хезмәтләре татар халкы (шул исәптән Казан төркиләре, Сөембикә манарасы) тарихына, әдәбият һәм тел белемена, ислам философлары, руханилары, татар мәгариф, мәдәният, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләренә карый. Аның беренче язмасы (мәрсиясе) 1903 елда Троицкида дөнья күрә. Ул шундагы «Рәсүлия» мәдрәсәсе башлыгы Зәйнулла Рәсүлевнең унбиш яшьлек улының фажигале үлемена багышланган була. Татар халкы өчен Батталның аеруча әһәмиятле хезмәтләре арасында — «Татар тарихы» (1912), «Рус ихтилалыннан хатирәләр» (1947), «Казанлы төрки мәшһүрләре» (1958–1959). Соңгысында татар халкының 1917–1920 еллардагы милли-мәдәни мөстәкыйльлек өчен көрәш сәхифәләре яктыртыла, автор шул вакыйгаларның үзәгендә була, дүрт басмада («Ризаэтдин Фәхретдин улы», «Муса Җарулла Биги», «Галимҗан Баруди» һәм «Ике бертуган Максудилар». «Галимҗан Баруди») тасвир ителгән шәхесләр белән якын мөнәсәбәттә тора. Шулай ук 1930–1940 елларда ул башкарган тәрҗемә хезмәтләрнең иң күренекле ләре: «Ибне Мөһанна лөгате» (1934) һәм 2 томлык «Кыргыз теле сүзлеге» (1945, 1946). Төркиядә нәшер ителгән «Төрек йорты», «Яңа Төркестан», «Төрек теле», «Төрек мәдәнияте» һәм башка газета-журналларда тел, әдәбият, тарих мәсьәләләренә караган мәкалә-очерклар бастыра.



Г.Г.Баттал

Беренчеләрдән булып, татар көндәлек матугатында Каюм Насыйриның эшчәнлеге турында язып чыга. Аерым алганда, «Йолдыз» газетасында 1912 елның октябрендә «Телебез» дип аталган күләмле мәкаләсе дөнья күрә. Анда галимнең татар телен үстерүдәге роле түбәндәгечә билгеләнә: «Үз арабыздан чыгып, үз телебезне

тергезү нияте белән кулына каләм тоткан затларның иң олугсы Габделкаюм ән-Насыйри абзыйдыр. Ул телебезне төзәтер өчен халык әдәбиятының иң мөһим нигез булуын аңлап, армый-талмыйча җырлар, мәкальләр, табышмаклар, әкиятләр җыйды да, аларны «Фәвакиһел-җөләса» атлы олуг әсәрендә беркетеп калдырды. Ул мөхтәрәм зат башлап татар теленә «Ләһҗәи татари» исемле лөгать китабын язды. Бу җәһәттән руслар арасында Даль нинди урын алса, Габделкаюм абзый да бездә шул урынны шөгыльләнәдер. Моннан башка ул татар теле белән ничәмә-ничә тәрҗемәләр вә әсәрләр мәйданга китерде. Ул татар теле белән әхлакый китаплар да, җәгърәфия китапларын да, тарихи әсәрләр дә, төрле кыйсса вә әкиятләр дә тәэлиф [җыйнау] вә тәрҗемә итте. Габделкаюм абзый «Мәҗмугаи әсәр»ендә күләме игътибары белән күп язучы мөхәррирләрдән саналырга тиеш вә телебезгә иткән хезмәтләре ягыннан әдәбият тарихыбызда иң беренче урынны тотарга мөстәхикъ [лаеклы] бер заттыр. Ул татар телен тергезү белән генә канәгатьләнмичә, татар балаларына рус телен өйрәтергә дә тырышты: башлап русча-татарча зур лөгать [словарь] язды; русның сарыф вә нәхүен өйрәтер өчен дә шәкерт җәмәгатьләренә иң җайлы бер ысул тотып «Нәмүнә» исемле калын гына бер әсәр тәэлиф итте. Аның бу соңгы әсәрләре дә татар теленең эшләнүенә вә гыйлем теле булуына зур хезмәт иткәннәр». К.Насыйриның исеме онытылып барганлыгына борчылуын белдереп: «Үзенең мазыйын [үткәнен] онытмаган бу милләт арамыздан кичә генә гаиб булган Габделкаюм абзыйны да онытып бара. Татар теленең атасы, гыйлем вә әдәб хадиме [хезмәткәре], безнең ише ялкау халыктан бик сирәк чыга торган бер тырыш вә эш сөюче кеше булган бу затны, ничөндер, халкыбыз тәкъдир итә алмый. Әллә нинди гарәпләрне, персияннарны казып чыгарып, тәрҗемәи хәлләрен беренче сәхифәсеннән баскан «Шура» мәҗмугасы да Габделкаюм абзыйны игътибарга алмады. Ихтимал, остаз Ризаэтдин хәзрәт (*Фәхретдин* Ризаэтдин) аны «Асар»га язмый калмагандыр, ләкин Габделкаюм абзыйга ул гына аз. Тик Шиһабетдин хәзрәтнең (*Мәрҗани* Шиһабетдин) исемен тергезергә тәшәббес иткән [тырышкан] затлар кебек гайрәт вә хәмият [саклау] ияләре бервакыт Габделкаюм абзыйны да сагынырлар, аның исемен дә тергезеп, хезмәт вә гамәлләрен мөкәммәл сурәттә язып, халкыбызга танытырлар дигән өмид белән генә юанырга каладыр», — дип яза.

Хезм.: Ислам философлары Мөхәммәд Габдеһ вә Җамалетдин Әфгани. Казан, 1908; Мәгыйшәт юллары. Казан, 1908; Татар тарихы. Казан, 1912; Телебез // Йолдыз. 1912. 11 октябрь; Назарияте әдәбият. Казан, 1913; Өч төрле идарә ысуллары: чикләнмәгән монархия, чикләнгән монархия һәм җөмһүрият. Казан, 1917; Ана теле сарыфы. Казан, 1918 (автордаш); Казан төркиләре. Казан, 1996; Rusyadan Ayrılan Milletler. Ankara, 1927; Rus ihtilalinden hatiralar. Istambul, 1947; Sadri Maksudi Arsal // Dergi. Munih, 1957; Kazanlı turk meshurleri. Istambul, 1958–59; Kazan turkleri. Istambul, 1989.

Әд.: Габделбарый бине Габдулла бине Мөхәммәтрәхим бине Сәетбаттал // Заман календаре. 1917; Хәмидуллин Л.Х. Онытылган якын исем // Татарстан. 1996. № 11; Султанбеков Б.Ф. «Одиссея» Бари Баттала // Татарстан. 1992. № 5/6.

Д.М.Госманова, Р.Ф.Исламов.

БАТЫ́РШИНА (Насыйрова) Гүзәл Гомәр кызы (09.05.1976, Татарстанның Аксубай районы Түбән Та-

тар Майнасы авылы), укытучы, филолог, филология фәннәре кандидаты (2002).

Казан университетының Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетын тәмамлаганнан соң, 1998–2001 елларда шунда ук аспирантурада укый. 2002–2013 елларда — Казан аграр университетының татар һәм рус телләре кафедрасында өлкән укытучы. 2015 елдан — Россия Ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы доценты.

Фәнни хезмәтләре тел тарихы, татар теле укыту мәсьәләләренә карый. Каюм Насыйриның татар тел гыйлемендәге эшчәнлеген өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклый (2002), мәгърифәтче галимгә багышланган күпсанлы мәкаләләр авторы.

Хезм.: Каюм Насыйриның телара сүзлекләр өлкәсендәге эшчәнлеге («Татарча-русча лөгать китабы») // Татар теле, әдәбияты, тарихы — үткәне һәм бүгенгесе. Казан, 2000; Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлеге: сүзләрне аңлату принциплары // Фән һәм тел. 2001. № 4; Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлегендә фразеологизмнар // Фәнни язмалар – 2001. Казан, 2002; Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. Казан, 2007; Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» сүзлегендә фольклор үрнәкләре // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика. Казань, 2021 (автордаш).

Ф.Г.Камальтдинова.

БАҺАВЕТДИ́НОВА Дания Борһан кызы (07.01.1932, Татарстанның Кама Тамагы районы Әмәкәй авылы – 28.08.2005, Казан; туган авылында җирләнә), педагог, фәнни хезмәткәр. ТАССРның һәм РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1986, 1987).



Д.Б.Баһаветдинова

Казан педагогия училищесын (1951), Казан университетын (1956) тәмамлый. 1957–1963 елларда — Максим Горький музеенда фәнни хезмәткәр, фонд мөдире. 1963–1967 елларда — В.И.Ленин исемендәге Дәүләт китапханәсенең (хәзер ТР Милли китапханәсе) матур әдәбият бүлегендә библиограф, 1967 елдан — ТАССР Дәүләт музеенда (хәзер ТР Милли музее): фәнни хезмәткәр (1967–1971, 1994–1999), әдәбият бүлеге мөдире (1971–1993) булып эшли.

Музейда эшләү дәверендә күпкырлы хезмәткәр (истәлекләрне туплаучы, тикшеренүче, экспозицияләр белгече, педагог, публицист, татар халкының әдәби мирасын пропагандалаучы) буларак таныла. Гафур Коләхмәтов, Һади Такташ, Кәрим Тинчурин, Сәгыйть Сүнчәләй, Шәйхи Маннур һәм башка язучыларның архивларын туплый. Республиканың төп музеенда татар әдәбияты тарихы буенча беренче экспозиция (1972) төзүче-авторларының берсе. 1976 елдан «Төп нөсхә көне» дип аталган, традициягә кергән «Моабит дәфтәрләре»н күрсәтү чарасын башлап җибәрүче. Арча районы Кырлай авылында Габдулла Тукай музеен (1979), Казанда Шәриф Камал (1986), Муса Җәлил (1983) музей-фатирларын, Габдулла Тукай музеен (1986), Балтач районының Шода авылында Мирхәйдәр Фәйзи музей-утарын (1991), Карадуган авылында Себер тракты тарихы музеен (1995), Мамадыш районының Тулбай авылында Шәйхи Маннур мемориаль музей-китапханәсен (1995),

Казан мәктәпләренең берсендә һәм Спас районының Көек авылында Абдулла Алиш музейларын оештыруда башлап йөри.

Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулу уңаеннан 1975 елның 11–12 февралендә Казанда уздырылган конференциядә «ТАССР Дәүләт музеенда Каюм Насыйри фонды» темасына доклад белән чыгыш ясый. Галимнең фондтагы шәхси әйберләре, үзе исән вакытта чыккан китаплары турында бәян итә, 1945 елда тууына 120 ел тулу уңаеннан оештырылган күргәзмәдәге материалларның музей фондына тапшырылуын, әдәбият бүлегендә алардан Каюм Насыйри почмагы булдырылуын, 19 йөз уртасы глобусы һәм үзе төзегән шәҗәрә аеруча кыйммәтле экспонатлардан саналуын ассызыклый.

«1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәте өчен», «Хезмәт ветераны» медальләре, ТР Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы (1997) белән бүләкләнә.

Хезм.: Фонд Каюма Насыри в Государственном музее ТАССР // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Музей Габдуллы Тукая в Казани: Путеводитель. Казань, 1989.

Әд.: Карташева Е.И. Мастер литературных экспозиций: памяти Д.Б.Багаутдиновой // Ежегодник – 2005. Национальный музей Республики Татарстан. Казань, 2006.

Ф.Г.Камальтдинова.

БАЯЗИ́ТОВ Гатаулла (1846, Рязань губернасының Касыйм өязе Төмәнсу авылы – 21.04.1911, Санкт-Петербург), илаһият галиме, мөгаллим, публицист, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Я.С.*Әхмәтгалиеваның* (Янбаева) бабасы Мөхәммәдсафа Баязитовның әтисе.

Башлангыч белемне атасы Баязит Шаһсуаров мәдрәсәсендә ала. Укуын Касыйм шәһәре янындагы Чутай авылының «Байморат» мәдрәсәсендә, соңрак Казан губернасының Казан өязе Кышкар авылы мәдрәсәсендә дәвам итә. Укуын тәмамлагач, Чутай авылы «Байморат» мәдрәсәсендә мантыйк һәм фәлсәфә укыта. 1871 елда Санкт-Петербургка чакырыла, анда 2 нче мөселман мәхәлләсен җитәкли, соңрак хәрби ахун итеп билгеләнә. Бер үк вакытта Россия Тышкы эшләр министрлыгы Азия департаментының Шәрекъ телләре бүлегендә тәрҗемәче һәм төрки телләр укытучысы булып эшли, Санкт-Петербургның төрле уку йортларында, шул исәптән Пажлар корпусында ислам дине нигезләрен укыта.



Г.Баязитов бюсты. Скульптор В.Абдуллина. 2011.

1880 елларда, татар һәм рус телләрендә «Һәфтә» («Атна») газетасы чыгарырга рөхсәт сорап, хакимияткә мөрәҗәгать итә. Үтенече кире кагылгач, башка газеталар чыгарырга омтылыш ясый. Бу үтенечләре дә канәгатьләндерелми. 1905 елда «Нур» газетасын гамәлгә куя, аның нашире һәм мөхәррире була. Газета чыга баш-

лау белән, киң катлау укучыларга: «Нинди телдә языйк? Төрек-госманлы теленме яки борынгы иске татар телемезнеме алыйк?» — дип мөрәҗәгать итә. «Әдәби телебез нә делдер?» дип башланган фикер алышуда Каюм Насыйри фикеренә дә игътибар бирелә: «Каюм Насыйров кебек гарәп-фарсы алынмалары беләнме, Фатих Кәрими яки Ризаэтдин Фәхретдин әсәрләрендәге кебек госманлы сүзләрен дә кулланыйкмы?» дигән сорау куела.

1881 елда Санкт-Петербургта, мәчет салдырырга рөхсәт сорап, хакимияткә мөрәҗәгать итә. 1906 елда хөкүмәт тарафыннан расланган мәчетне төзү өчен Махсус иганә җыю комитетын җитәкли. 1910 елда Петербург җамигъ мәчете нигезенә беренче таш салу тантанасы була.

1880–1890 елларда язган хезмәтләре Россиядә һәм чит илләрдә (төрек һәм француз телләренә тәрҗемә ителә) танылу ала. Аның «Эрнст Ренан чыгышына тәнкыйть» китабы (Санкт-Петербург, 1883) француз галиме Ренанның «ислам белән төгәл фәннәр яраклаша алмый» дигән идеяләренә каршы чыга һәм ислам тәгълиматының мантыйкка һәм фәнни гыйлемнәргә каршы килмәвен исбатлый. Ул авторның исламны җитди фәнни методологиягә нигезләнмичә тикшерүен тәнкыйть итә. «Исламның фәнгә һәм башка диндәгеләргә мөнәсәбәте» хезмәтендә (Санкт-Петербург, 1887) Баязитов башка дин вәкилләренә карата ихтирам исламның әсаси [нигез] принципларыннан берсе булуын дәлилли; мөселманнарның рухи халәтен татар җәмгыятенең эчке ихтыяҗларыннан, шулай ук Россиядә барган вакыйгалардан чыгып бәяли.

Педагог К.Д.Ушинскийның «Родное слово» дәреслегенә охшатып, балалар өчен гыйбрәтле хикәяләр һәм төрле мәкальләрне эченә алган «Дөнья яки мәгыйшәт» (1883) дәреслек-уку кулланмасы әзерли. Рухани, мөгаллим, хөкүмәт чиновнигы һәм башкала мөселманнары җәмгыятенең хакимият ышанычын яулаган җитәкчесе булып таныла. Милләт, дин, тел язмышы өчен борчыла. Һәр чыгышында диярлек милли бердәмлек, оешканлык идеясен алга сөрә. «Нур» газетасының 1911 ел 15 апрель санында басылган мәкаләсендә: «Без, Руссия татарлары, үзара булган каршылыкларны ташлап, тәрәкъкый вә мәдәни эшләр илә мәшгуль булырга тиеш», — дип яза.

2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав, Бохара әмире, Иранның «Арыслан һәм кояш» орденнары, Станислав тасмасына беркетелгән «Тырышлык өчен» алтын һәм көмеш медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Ислам китабы: 2 нче басма. Казан, 1880; Магомет как пророк. СПб., 1887; Ислам и прогресс. СПб., 1898;

Әд.: Беккин Р.И. Гатаулла Баязитовның соңгы гозере // Фәнни Татарстан. 2017. № 3; Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). Казан, 2015. 1 т.; Аминов Д.А. Татары в Санкт-Петербурге. СПб., 1994; Мухаметшин Р. Гатаулла Баязитов // Исторические портреты. Татарская интеллигенция и духовная культура. Казань, 2000; Хуснетдинов Р.М. Татарский письменно-литературный язык на страницах газеты «Нур» («Луч») и журнала «Шура» («Совет») // Научный Татарстан. 2009. № 4; Янбаева Я. Потомки Баязитова. Казань, 2009.


Р.М.Мөхәммәтшин,
Ф.Г.Камальтдинова.

БӘДИГЬЙ Хуҗа Габделбәдыйгъ улы (24.12.1887, Казан губернасының Мамадыш өязе Югары Бөрсет авылы – 17.11.1940, Казан), тел галиме,

фольклорчы, педагог, филология фәннәре кандидаты.

Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1900–1908). 1906 елның көзендә Идел төбәгендә яшәүче төрки халыкларны һәм аларның телләрен өйрәнү максатында Казанга венгр этнографы, антропологы һәм фольклорчысы Дьюла Мессарош (1883–1957) килә. Аңа ярдәмче итеп «Мөхәммәдия»дә укучы Бәдигыйне билгелиләр, ул, 5 ай дәвамында аның белән авыллар буенча йөреп, венгр галименә Идел төбәгендә яшәүче төрки халыкларның матди һәм рухи байлыклары турында мәгълүматлар җыярга ярдәм итә. Бу хезмәттәшлек аның фольклор галиме булып китүендә зур роль уйный. 1918 елга кадәр үзе укыган мәдрәсәдә мөгаллим булып эшли. 1918–1926 елларда Казанда Каюм Насыйри исемендәге Татар педагогия техникумында, татар хатын-кыз укытучылары әзерләү курсларында, Шәрекъ академиясе каршындагы эшчеләр факультетында татар һәм башкорт кызылармиячеләре арасында укырга-язарга өйрәтү курсларында, өлкә совет партия мәктәбендә, Мулланур Вахитов исемендәге икенче баскыч мәктәптә укыта, Татарстанның Мәгариф халык комиссариаты карамагындагы Гыйльми үзәктә эшли. 1926 елның көзендә Гыйльми үзәк Х.Бәдигыйне Ленинград көнчыгыш институтына укырга җибәрә, аны тәмамлагач, ул укуын шунда ук аспирантурада дәвам итә, академик А.Н.Самойловичта төрки телләр буенча тулы курс тыңлый, «Төрки телләрнең чагыштырма морфологиясе» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. 1930 елдан Казан педагогия институтында эшли, 1938 елда профессор дәрәҗәсенә ирешә.

Гыйльми эшчәнлеге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган вакытта ук башлана, «әл-Ислах» газетасында мәкаләләре басыла. Фәнни хезмәтләрендә татар теле мәсьәләренә зур игътибар бирә. Татар теленең фонетик, грамматик, лексик нормаларын өйрәнеп, «Ана теле сарыфы» (1918), «Ана теле нәхүе» (1919), «Рус мәктәпләре өчен татар теле дәреслеге» (1923, 1925, 1926; Мөхетдин Корбангалиев, Галимҗан Шәрәф белән автордашлыкта), «Шәкли нигездә гамәли тел сабаклары» (1925; Корбангалиев белән автордашлыкта), «Сөйләү теле буенча дәресләр» (1925), берничә басмада «Тел сабаклары» (1929), «Татар теле грамматикасы дәресләре» (1931), «Грамматика. Беренче кисәк. Морфология» (1933, 1934, 1936), «Әлифба» (1937, Корбангалиев белән автордашлыкта), «Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. Яңа басма» (1938) дәреслекләрен һәм башка хезмәтләрен нәшер итә.



Х.Г.Бәдигый

Каюм Насыйри мирасын җентекле өйрәнә. «Каюм Насыйри мәҗмугасы» (1922) җыентыгында дөнья күргән күләмле «Каюм Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлында хезмәтләре» мәкаләсендә галимнең бу юнәлештәге эшчәнлеген түбәндәгечә бәяли: «Ләкин ул җыйган материалларын һәм тәфтишләрен аерым бер мәҗмуга рәвешендә бастыра алмаган. Бәлки үзенең төрле әсәрләре арасына кертеп яки Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә биреп нәшер иткән». Аның «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» исемле хезмәтендә 28 табышмак, 118 җыр, 3 бәет, 315 мәкаль тупланганлыгын ачыклый; «Кырык бакча» китабында берничә мәсәл барлыгын күрсәтеп, аларның

саф халыкныкы булуына шик белдерә. 1881, 1883, 1885 еллардагы Казан календарьларында теркәлгән «Казан бәете»нә, «Шаһгали бәете»нә, төрле риваятьләргә («Иске Казанның һәм яңа Казанның салынулары», «Әмәт тавы», «Елан тавы», «Алып адәмнәр», мунча себеркесе, чәй, каһвәнең һ.б.ның кулланылышка кереп китүе) тукталып уза. «Әнмүзәҗ» грамматика китабында 75 тәгъризәт, ягъни читләтеп әйтелә торган сүзләр китерелгәнлегенә игътибар итә. «Ләһҗәи татари» сүзлегендә шулай ук күп кенә борынгы мәкальләр, табышмаклар, читләтеп әйтелә торган сүзләр табарга мөмкин булуын ассызыклый.

К.Насыйриның «Император Рус география җәмгыяте хәбәрләре»нең 1880 елгы 6 нчы томында басылган «Казан татарларының игътикад [ышанулары] һәм гадәтләре» мәкаләсендә төрле хорафатлар һәм имләгәндә әйтелә торган такмаклар барлыгын билгеләп үтә. Галимнең «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»нең 1896 елгы 13 нче томында дөнья күргән «Казан татарларының халык әдәбияты нәмүнәләре [үрнәкләре]» мәкаләсендә рус теленә тәрҗемәләре белән 28 табышмак, 244 мәкаль, 116 халык җыры һәм бер «Сәламнамә» бәете урын алуын раслый. Шул ук басманың 1899 елгы 15 нче томында профессор Н.Ф.Катанов бастырган «Казан татарларының тарихи җырлары» мәкаләсендәге өч бәетнең К.Насыйри тарафыннан бирелгәнлеген искәртә. «Хәбәрләр»нең 1900 елгы 16 нчы томында П.А.Поляков белән берлектә бастырган күләмле «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны бүтән халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» мәкаләсендә «Салам Торхан», «Җүләр угыл», «Уги кыз», «Гөлнәзек», «Байдек», «Өч угыл», «Гакыллы бала», «Төлке», «Мәче белән аю», «Аю белән төлке», «Сандугач белән бытбылдык», ягъни 11 халык әкиятенең өйрәнелүе турында яза.

Репрессияләр чоры корбаны: 1938 елның 29 июнендә «Идел-Урал» буржуаз-милли оешмасы эшчәнлегендә катнашуда гаепләнеп кулга алына. 1940 елның 22 июнендә аклана.

Хезм.: Ана теле сарыфы. Казан, 1918; Ана теле нәхүе. Казан, 1919; Каюм Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлында хезмәтләре // Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Grammatika. Berence kisək. Morfologiə. Qazan, 1929; Тел сабаклары. Казан, 1929; Сайланма хезмәтләр. Татар халык иҗаты әсәрләре. Казан, 2001.

Әд.: Исламов Ф. Хуҗа Бәдигый — танылган телче, фольклорчы, педагог һәм методист: 1887–1940 // Фән һәм тел. 2003. № 1; Мәхмүтов Х. Хуҗа Бәдигый тапкан хәзинәләр: Х.Бәдигый. Танылган телче, фольклорчы, педагог һәм методист // Фән һәм тел. 2003. № 1; Хаков В. Хуҗа Габделбәдигъ улы Бәдигый // Мәдәни җомга. 1997. 19 декабрь; Хуҗа Бәдигый — тел галиме / төз. Э.Х.Кадирова, Д.М.Мөхәммәтҗанова. Казан, 2021; Ягъфәров Р. Х.Бәдигый // Казан утлары. 1977. №12.

Р.Ф.Исламов.

БӘЕ́Т (гарәп теленнән — بيت «өй», «шигырь»; угыз телләрендә — бөй/бәй «хикәя», «җыр»), татар халык авыз иҗатының берәр шәхескә яки мөһим вакыйгага багышланган, күпчелек очракта фаҗигалелек, сагыш, кызгану хисләре белән сугарылган борынгы лиро-эпик жанры.

Татар әдәбият белемендә бәет — язма һәм сөйләм формаларындагы, көйләп яки көйсез әйтелүче ике юллыклардан торган шигъри әсәр (2 дән 500 строфага кадәр). Идел-Урал буе татарлары иҗатына хас. Жанр буларак

14–15 йөзләрдә барлыкка килә. Өч төргә бүленә: шәхси фаҗига бәетләре; сатирик бәетләр; сугыш бәетләре.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, аны өйрәнүгә һәм бастырып чыгаруга аеруча зур әһәмият бирелә. Ул татар халык *әкиятләрен, җырларын, мәкальләрен, сынамышларын, табышмакларын, риваятьләрен, ырымнарын, ышануларын* барлау белән бергә, Казан, Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендә яшәүче татарлар арасында йөргән бәетләрне җыюны мөһим бурычы итеп саный. Бәетләрне махсус өйрәнә башлау аның исеме белән бәйле. Аның тарафыннан «Казан бәете» («Казан тарихы»), «Рус-француз сугышы бәете», «Җыен бәете», «Чәй бәете», «Уңмаган килен», «Сәламнамә», «Гыйшык сүзләре» һәм башка бәетләр язып алына.

Әлеге бәетләр эчтәлекләре белән төгәл тарихи вакыйгаларга, татар халкының гореф-гадәтләренә һәм тормыш-көнкүреш хәлләренә бәйле. Алар тематикасы буенча күптөрле, мәсәлән, «Казан бәете» Идел буе татарлары тормышындагы зур бер дәвернең — Идел буе Болгар дәүләтенең җимерелүеннән (13 йөзнең 1 нче яртысыннан) алып Казанның һәм Казан ханлыгының Рус дәүләтенә кушылуына (16 йөзнең 2 нче яртысы) кадәрге чорның мөһим тарихи вакыйгаларына багышлана, анда болгар-татар тормышындагы аеруча киеренке хәлләр яктыртыла; халык каһарманнары Әбелхаликъ белән Чура батыр да мөһим урынны алып тора. «Казан бәете»н К.Насыйри беренче тапкыр 1881 елгы календарьда бастырып чыгара. 1899 елда аның русчага тәрҗемәсен Н.Ф.*Катанов* нәшер итә.

«Рус-француз сугышы бәете»ндә 1812 елгы сугыш Ватан азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барган гадел көрәш буларак тасвирлана. Дәһшәтле француз императоры Наполеон халык арасыннан чыккан солдат образына каршы куеп сурәтләнә. Н.Ф.Катанов мәгълүматлары буенча, К.Насыйри җыйнамасында «Французлар һәм Николай I турында җыр»ның бер кулъязмасы була, ул аның ахырына үз кулы белән «1855 нче елның 12 февралендә тәмамланды» дип язган. Соңыннан әлеге әсәрне Н.Ф.Катанов «Казан татарларының тарихи җырлары» мәкаләсендә «Николай бәете» исеме белән бастыра.

«Җыен бәете» — К.Насыйри җыйнамасына кергән көйле нәсыйхәт характерындагы тезмә әсәр. Ул 1881 елда Казан университеты басмаханәсендә кечкенә форматта басылып чыга. Бәеттә Казан арты авылларындагы җыеннар, аларга Казан халкының кайтуы, татарларның Җыен бәйрәмен үткәргәндә акчаларын әрәм-шәрәмгә тотулары һәм бурычка батулары турында бәян ителә. «Уңмаган килен» бәетендә кияүгә чыккан ялкау, булдыксыз, комсыз һәм миһербансыз хатын-кызлар сурәтләнә; «Гыйшык сүзләре» бәете мәдрәсә шәкертләре язган мәхәббәт хатларының стилен чагылдыра.

«Чәй бәете»ндә 19 йөздә татар халкы, аеруча байлар һәм муллалар көнкүрешенә актив рәвештә үтеп кергән самовардан чәй эчү традицияләре ирония белән тасвирлана. К.Насыйри яшәгән чорда самовар гаиләнең матди хәлен күрсәтә торган көнкүреш предметына әверелә, өйдәге чүкеп бизәлгән бакыр яки латунь самовар аерым әһәмияткә ия була. Габделгалләм Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» («Хикәяләр һәм мәкаләләр», 1889) китабында бәетнең бер Казан мулласыныкы икәнлеге искәртелә. Ләкин әлеге текстта сүзләр кулланылышында аермалар бар.

К.Насыйри еллык календарьларының кайбер саннарында, 1880 елда басылып чыккан «*Кырык бакча*» җыентыгында «Сәламнамә», «Мәдхе чәй», «Уңмаган килен» һәм «Әбъят», 1884 елда дөнья күргән «*Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият*» китабында «Әбъят Мәхбүбләргә сәламнамә», «Әбъят чәй бәянында», «Әбъят уңмаган килен бәянында» исемле бәетләр китерелә.

Әд.: Бәдигый Х. Каюм Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлында хезмәтләре // Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Габделбәдигъ Хуҗа. Халык әдәбияты. Бәетләр. Казан, 1935; Бәетләр. Казан, 2000; Гали М. «Җыен» бәете // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; Насыйри К. Казан бәетендә мәзкүр Үлмәс вә Әбелгалак хакында риваять // Календарь 1881 нче елга. Казан, 1880; Татар халык иҗаты: Бәетләр. Казан, 1983; Фәезханов Г. Хикәят вә мәкаләт. Казан, 1889. Язучы мөтәрҗим. Казан татарларының тарихи җырлары // Шура. 1911. № 17; Катанов Н.Ф. Исторические песни казанских татар // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1899. Т. 15, вып. 3; Лукина А.Р. Каюм Насыри о татарских народных песнях и баитах // Вестник Чувашского университета. 2010. № 1.

Р.В.Шәйдуллин.

БӘХТИЯ́РОВ Вафа (Әхмәтвафа) Гали улы (09.12.1881, Саратов губернасының Хвалынск өязе (хәзер Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка районы Зимница авылы) – 1960, Казан), журналист, укытучы, Каюм Насыйри турында истәлек авторы; Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирханның дусты.

Зимница авылы мәдрәсәсен тәмамлый, 1900–1901 елларда — Казанда Яңа Бистәдәге Иске Таш мәчете каршындагы «Әмирхания» мәдрәсәсендә,



В.Г.Бәхтияров

1902 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Шәкертләрнең яшерен сәяси оешмасы — «әл-Ислах» комитеты эшендә актив катнаша. 1907–1909 елларда — «әл-Ислах» газетасының рәсми нашире һәм мөхәррире. Газетада актуаль темаларга караган материаллар бастыра, мөселман дини мәктәпләрен үзгәртеп кору мәсьәләләрен күтәрә. 1909 елдан — Казанда «Аят мәктәбе» укытучысы. 1950 елларда эшче яшьләр мәктәбендә укыта.

В.Бәхтияров белән Хөсәен Әбүзәров, Каюм Насыйри яшәгән өйдә булып, аңардан «Русча-татарча сүзлек», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимеше»), «Ләһҗәи татари» («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге») китапларын сатып алалар. Шулай ук 1902 елның августында Каюм Насыйриның җеназасында була. Анда 25 ләп кеше катнашуын, галимнең шәхесенә бәрабәр хөрмәт белән озатылмавын, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең кайбер укытучылары җеназада катнашмауны берничек тә аңлатып булмавын искәртә; аерым татар морзаларының, Казанның башлангыч рус мәктәпләрендә эшләүче татар укытучыларының бу гамәлләрен хөкүмәттән, шул заман сәясәтеннән куркулары белән аңлата. Әлеге истәлекләр ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә саклана. Беренче тапкыр 2017 елда «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык»та басылып чыга. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017.


Ф.Г.Камальтдинова.

БӘХТИЯ́РОВ (Бәхтияри) Зыя (Мөхәммәтзыя) Бәхтияр улы (28.02.1877, Казан губернасының Казан өязе Мәмдәл авылы (хәзер Татарстанның Биектау районы Мәмдәл авылы) – 18.01.1974, Киров өлкәсе Малмыж районы Яңа Смәил авылы), мулла, мөгаллим, дәреслекләр һәм кулъязма китаплар авторы, мәгърифәтче, тарихчы, Каюм Насыйри шәкерте.

Башлангыч белемне әтисе — указлы имам Бәхтияр әл-Мәмдәли хәзрәттән ала, аннары укуын Түнтәр мәдрәсәсендә (Вятка губернасының Малмыж өязе Түнтәр (хәзер Татарстанның Балтач районында) авылындагы дини уку йорты) дәвам итә. 1902 елда Вятка губернасының Малмыж өязе Яңа Смәил авылына мулла итеп билгеләнә. Иганәчеләр ярдәме белән яңа мәчет, яңа мәдрәсә бинасы салдыруга ирешә.

Шәкерт вакытында ук Бәхтияров ике китап яза, беренчесе 1898 елда — Казан университетының басмаханәсендә «Каванин әл-хисаб» («Арифметика»), икенчесе 1903 елда бертуган Кәримовлар басмаханәсендә «Горрәи даими» («Мәңгелек календарь») исемнәре белән дөнья күрә. Аларны язган вакытта киңәш алу максаты белән Каюм Насыйри янына еш килеп йөри. Аны аеруча галимнең медицина өлкәсендәге гыйлемнәре кызыксындыра, аннан дәвалау ысулларын өйрәнә, шифалы үләннәрдән файдалану буенча тәжрибә туплый. К.Насыйридан өйрәнгән дәвалау гыйлеме белән мулла авылдашлары алдында абруй казана.

К.Насыйрига бәйле истәлекләре әдәбият галиме Мөхәммәт *Гали* тарафыннан язып алына һәм 1948 елда мәгърифәтчегә багышланган җыентыкта бастырыла. Үзенең истәлекләрендә К.Насыйриның киңкырлы шәхес булуын, янына белем эстәү ниятe белән күп кенә муллалар, шәкертләрнең килеп йөрүен, шулай ук яшь шәкертнең гыйльми мәсьәләләр буенча киңәш сорап килүенә шат булуын искәртеп уза. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.



З.Б.Бәхтияров

Хезм.: Каванин әл-хисаб. Казан, 1898; Горрәи даими. Казан, 1903; Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Смәил тарихы. Кулъязма китап. Яңа Смәил, 1961.

Әд.: Мортазина Л.Р. Мөхәммәтзыя Бәхтияров — дәреслекләр һәм кулъязма китаплар авторы // Фәнни Татарстан. 2018. № 3.

Ф.Г.Камальтдинова.

БӘЯЛӘМӘ, язма һәм сөйләм жанрларының берсе. Фәнни, фәнни-популяр, ижади әсәрләргә тәнкыйди бәя бирү (аларның актуальлеге, эчтәлеге һәм стиле үзенчәлекләре турында күзаллау), яңа әсәр-хезмәтләр турында хәбәр итү, укучының игътибарын юнәлтү һәм аларга карата кызыксынуын уяту бурычын башкара; төп асылы җәмәгатьчелек фикерен формалаштырудан, фән, әдәбият, сәнгать үсешен һәм аның киләчәген фаразлаудан гыйбарәт.

Каюм Насыйриның әсәрләренә, дәреслекләренә, хезмәтләренә һәм тәрҗемәләренә ул яшәгән чорга хас консерватив карашлардан чыгып бәя бирүчеләр күп була. Алар арасында кадимче муллалардан тыш шактый гына татар зыялылары да (шул исәптән

Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин) очрый. К.Насыйриның Европача гыйльми һәм мәдәни агарту эшчәнлегенә традицион күзлектән карап, күпләр аны татар халкының дини һәм иҗтимагый-мәдәни тормышын руслаштыру сәясәте алып баруда гаеплиләр һәм галимне төрлечә кыерсыталар. Шул ук вакытта К.Насыйриның татар халкының белем һәм мәдәни дәрәҗәсен үстерүгә караган хезмәтләренә һәм мөгаллимлек эшчәнлегенә Казан университеты галимнәре (И.Ф.*Юстальд*, Н.Ф.*Катанов*, В.В.*Радлов*, Г.С.*Саблуков*, Н.А.Фирсов һ.б), Петербург университеты профессоры В.В.*Григорьев* һәм цензура комитетының татар китабы цензоры В.Д.*Смирнов* югары бәя бирәләр. Аның хезмәтләрен фәнни әйләнешкә кертүгә Н.Ф.Катанов зур көч куя. Ул «*Деятель*» журналында «Шәрекъ библиографиясе» бүлеген алып бара (бүлек эшеннән татар китапларының библиографиясен төзү башланып китә), укучыларны татар мәдәнияте белән таныштыруда әһәмиятле роль уйный (күпчелек мәкаләләрнең авторы була), бүлектә К.Насыйриның Казан университеты басмаханәсендә дөнья күргән хезмәтләрен тасвирлауга аерым игътибар юнәлтә. Әлеге журнал битләрендә аның 10 нан артык китабына үз бәяләмәләрен бастыра, шулар арасында басманың 1897 елгы 2 нче санында дөнья күргән «Кавагыйде лисане гарәб» («Гарәп теле грамматикасы») хезмәтен анализлап, аның отышлы якларын һәм шул ук вакытта кимчелекләрен дә күрсәтә. Дәреслек катгый система кысаларында бирелеп, һәр кагыйдә гарәп теленнән мисаллар белән ныгытылуга карамастан, сүзләрнең гарәп телендәге «а», «и», «у» сузыкларын һәм башкаларны аңлаткан билгеләр (хәрәкәләр) куелмау, өстәвенә китапның исеменнән гайре аның барлык эчтәлеге фәкать гарәп телендә генә булу, борынгы гарәп грамматикасы терминнарының мул кулланылуы, аларның да шул ук гарәп телендә генә аңлатылуы сәбәпле, Н.Ф.Катанов укучыларның әлеге дәреслекне грамматика укытучысыннан башка гына бер ел эчендә үзләштерә алмавы, бу очракта аның авторының аңарчы ук гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән балаларны һәм аларга сабак бирергә сәләтле мөгаллимне күздә тотуы хакында нәтиҗә ясый, татар галимнәренең гарәп грамматикасын үз телләрендә аңлатмавын «затлы гарәп телен тупас мужик аңлатмалары белән бозарга» теләмәүләрендә күрә; 1898 елгы 5 нче санда «Кабуснамә тәрҗемәсе»нең 2 нче һәм «Әхлак рисәләсе»нең 4 нче басмаларына күзәтү ясый, аларның киң даирәгә аңлаешлы, камил татар телендә язылуын ассызыклый; 1898 елгы 6–7 нче саннарда К.Насыйриның шул ук елда чыккан «Китап әт-тәрбия» («Тәрбия китабы») хезмәтенең 2 нче басмасына бәяләмә бастыра. Авторның балада чын кешелек сыйфатлары тәрбияләү асылын яктыртуын, гамәли дәлилләр сыйфатында башлыча Гарәбстанның һәм Иранның бөек шәхесләре тормышыннан китерелгән мисаллар рәвешендә тәкъдим ителгән кечерәк 86 хикәят урнаштыруын югары бәяли, 24 битлек брошюрадагы кайбер фикерләрнең Инҗилдәге якын кешегә карата мәхәббәт турындагы тәгълимат белән охшашлыгын искәрә. Шул ук елдагы 8–9 нчы саннарда К.Насыйриның яңарак кына чыккан «Җәваһир әл-хикәят» («Хикәяләрнең җәүһәре») әсәренең 5 нче басмасын күздән кичереп, аның 1505 елда вафат булган гарәп илаһият галиме һәм тарихчысы шәех Җәләлетдин Габдрахман ибне Әбүбәкер әс-Соютинең «Әнисел-җәлис» китабының татар теленә тәрҗемәсе һәм

тәкъва мөселманнар тормышының төрле күренешләре бәян ителгән 50 дән артык хикәятне үз эченә алуына басым ясый; 1901 елгы 5 нче санда Катанов галимнең «Сәнаигы гольфания» («Гальваника эшләре») хезмәтенә югары бәя бирә, авторның мөселманнар тарафыннан Европа фәне казанышларының сүлпән үзләштерелүенә борчылуын, хәзер гальваникага багышланган китабын нәшер итеп, үзенең диндәшләренә файда китерергә омтылуын белдерә.

Әд.: Катанов Н.Ф. Книга «Каваиди-лисани-араб» («Правила арабского языка») // Деятель. 1897. № 2; шул ук. «Кабус-наме терджемесе» (Перевод книги «Кабус-наме» // Деятель. 1898. № 5; шул ук. «Ахляк рисалесы» («О нравственности») // Деятель. 1898. № 5; шул ук. «Тербия китабе» («Книга воспитания») // Деятель. 1898. № 6–7; шул ук. «Джауагируль-хикаять уа ль-асъиле уа лятаифур-риуаять уа ль-амсиле» («Драгоценности рассказов и вопросы остроумия предания и притчи») // Деятель. 1898. № 8–9; шул ук. «Санаи гальфание» («Работы гальванические») // Деятель. 1901. № 5.

Р.В.Шәйдуллин.

БЕ́РКУТОВ Валентин Михайлович (10.02.1926, Татарстанның Мамадыш кантоны (хәзер Кукмара районы) Нырья авылы – 28.11.2015, Казан), педагог, педагогика фәннәре докторы (1993), профессор (1995). ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1992), Бөек Ватан сугышында катнаша.

Казан педагогия институтын тәмамлый (1954). 1960 елдан — Казан финанс-икътисад институтында, 1966 елдан — Казан югары танк училищесында, 1973 елдан — СССР Педагогия Фәннәре академиясе Гомуми педагогика фәнни-тикшеренү институтының Казан дидактика лабораториясендә, 1976 елдан — Казан ветеринария институтында, 1995 елдан Казан педагогия университетында эшли.



В.М.Беркутов

Хезмәтләре математик белемнәр һәм татарларда математика укыту тарихына карый. 1993 елда педагогия фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә дәгъвалаган «Татар халкында математик белем бирү үсеше (X йөз – XX йөз башы)» темасына якланган диссертациясендә Каюм Насыйриның әлеге фән тармагындагы фәнни-педагогик эшчәнлеген фәнни яктан җентекләп тикшерә. Диссертациянең 6 нчы бүлегендә («Революциягә кадәрге мәктәптә кулъязма математика чыганаклары (XVI–XIX йөзләр)») галимнең кулъязма хәлендәге «Хисаплык» («Арифметика яки арифметика курсы») һәм «Гыйльме һәндәсә» («Геометрия») хезмәтләрендә дәресләрнең җентекле планнары эшләнүгә, материалның укытучының балалар белән әңгәмәсе рәвешендә корылуына, күрсәтмә чараларның киң җәлеп ителүенә игътибар юнәлтелә. 8 нче бүлектә («Татар һәм рус-татар мәктәпләре өчен математика укыту әдәбияты (XIX йөз уртасы – XX йөз башы)») «Хисаплык»ның — 1873 елда, «Гыйльме һәндәсә»нең 1895 елда басылып чыгуы, аларның татар мәктәпләре укучылары өчен аңлаешлы телдә язылуы, математика кулланылу өлкәләре яктыртылган мисалларның һәм мәсьәләләрнең көндәлек тормыштан алынуы, К.Насыйриның әлеге дәреслекләрне иҗат иткәндә татар телендә математика фәнни терминнарын эшләве, аларның күбесе тотрыклы рәвештә татар әдәби теленә керүе һәм хәзерге вакытта да мәктәп дә-

реслекләрендә кулланылуы, галимнең методик нигезләмәләренең алга таба революциягә кадәрге чорда татар яшьләренең математик белем алуында зур роль уйнаган төрле фәннәр буенча әзерләнгән дәреслекләрдә (Габдулла Гыйсмәти, Ильяс Таһиров һ.б.ның хезмәтләре) чагылыш табуы ассызыклана.

Хезм.: Татарның мәшһүр математиклары. Казан, 1999; Из истории математического образования в Татарстане. Казань, 2003; Народный календарь и метрология булгаро-татар. Казань, 1987; Развитие математического образования булгаро-татар. Казань, 1997.

И.Х.Хәлиуллин.

БИККИНИ́ЕВ Шаһиәхмәт Сөләйман улы (1840, Казан губернасының Казан өязе (хәзер Татарстанның Биектау районы Урта Алат авылы) – ?), 2 нче гильдия сәүдәгәр, «Ш.Биккиниев уллары белән» сәүдә йорты хуҗасы, хәйрияче.

1895 елда 2 нче гильдия буенча сәүдәгәрлеккә кабул ителә. Йорты хәзерге Тукай урамында (90 нчы йорт) урнаша. Печән базарында кибете була. Мануфактура сату белән шөгыльләнә. 1875 елда аның матди ярдәме белән Каюм Насыйриның «Казан календаре 1875 елга» басыла.

Ф.Г. Камальтдинова.

БОРҺА́НОВА Рәшидә Габдрахман кызы (11.05.1943, Татарстанның Юдино (хәзер Яшел Үзән) районы Каратмән авылы), педагог, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы (1991), ТРның атказанган укытучысы (1998). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2007).

Казанның 1 нче педагогия училищесын (1972), Казан педагогия институтының Тарих-филология факультетын (1978) тәмамлый. Яшел Үзән районы Карагужа урта мәктәбен тәмамлаганнан соң (1960), Казанда «Тасма» җитештерү берләшмәсендә аппаратчы булып эшли. 1968 елдан — Яшел Үзән районы Олы Күлбаш авылы балалар бакчасы мөдире, 1974 елдан — Казанда 339 нчы балалар бакчасы мөдире, 1985 елдан — Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының мәктәпкәчә тәрбия кабинеты, мәктәпкәчә тәрбия һәм башлангыч мәктәпләр лабораториясе мөдире, 2001–2009 елларда ТР Мәгарифне үстерү институтының мәктәпкәчә тәрбия кафедрасы методисты вазифасын башкара.



Р.Г.Борһанова

Фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлешләре мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирү мәсьәләләренә, программалар, методик кулланмалар төзүгә карый.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар теле өйрәнә нәниләр. Казан, 1994 (автордаш); Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. Казан, 2000 (автордаш); Рус һәм татар телләренә өйрәтү мәсьәләләре // Мәгариф. 2002. № 6; Татарский орнамент в декоративно-прикладном искусстве // Воспитатель ДОУ (Москва). 2008. № 3.

Әд.: Сабыйларга ачкыч // Татарстан хәбәрләре. 1994. 5 август; Хәсәнова Ф. Ана теле, ана сөте һәм балалар бакчасы турында // Татарстан хәбәрләре. 1994. 21 май.

Ф.С.Гыйниятуллина.

БОТА́НИКА (грек теленнән botanikos — үсемлекләргә караган), үсемлекләр (аларның төзелеше, терек-

лек эшчәнлеге, классификациясе, таралышы, тарихи үсеше, табигать һәм кеше тормышындагы әһәмияте) турындагы фәннәр комплексы; биология фәненең төп бүлекләреннән берсе.

Үсемлекләр турындагы фән буларак бай тарихка ия. Бик борынгы заманнарда — кешеләр үсемлекләрне үзләренең гамәли ихтыяҗларын (ризык, дәвалану, торак, кием-салым һ.б.) канәгатьләндерү өчен куллана башлаганда барлыкка килә. Дистәләрчә гасырлар дәвамында үсемлекләр турында шактый мәгълүмат туплана, чөнки кешеләрнең тормышы файдалы, башлыча азык, дару һәм агулы үсемлекләр белән бәйле була. Үсемлекләр турындагы белемнәрнең бербөтен системасы буларак ботаника 17–18 йөзләрдә формалаша.

Татар халкы көндәлек тормышына үсемлекләрне система рәвешендә өйрәнү традицияләре Идел буе Болгар дәүләте чорыннан керә башлый һәм ул Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында яңача үсеш ала. Бу дәвердә төрки-татарларда ботаника буенча белемнәрне үстерү өчен төп чыганакларны медицинага караган көнчыгыш трактатлары, шул исәптән Әбугалисинаның «Шифа китабы» тәшкил итә. Аларда азык, дару, агулы һәм хуш исле үсемлекләр турында төрле мәгълүматлар китерелә. Шул хезмәтләр ярдәмендә дәвалаучы табиблар нинди дару үләннәрен, кайчан һәм ничек җыярга кирәклеген, аларның үзенчәлекләрен, алардан дарулар ясау ысулларын, гомумән, тирә-якта үскән үлән һәм чәчәкләрне өйрәнәләр, алар турында төрле мәгълүмат туплыйлар һәм кулъязма рәвештә киләчәк буыннарга теркәп калдыралар.

Каюм Насыйри татарлар арасында беренчеләрдән булып үсемлекләрне гыйльми яктан өйрәнә, үләннәр һәм чәчәкләр исемлеген барлый. Галимнең 1886 елда дөнья күргән «*Хәвасе нәбатат*» китабы — ботаника өлкәсендәге беренче фәнни хезмәте. Анда ботаника терминнары (тамыр, сабак, яфрак, кабык-кайры һ.б.) белән таныштырыла, 300 гә якын үсемлекнең төзелешенә һәм үсеш шартларына күзәтү ясала. 1894 елда ул аны эшкәртеп һәм тулыландырып, Казан университеты басмаханәсендә «*Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек*» хезмәтен бастыра. Аның ахырындагы «Гөлзар вә чәмәнзар китабына сүзлек»



К.Насыйри. «Гөлзар вә чәмәнзар». Казан. 1894.

кушымтасында үсемлекләрнең татарча, русча һәм латинча исемлеге бирелә. Китапның галим вафатыннан соң 1903 елда дөнья күргән икенче басмасында катлаулы дарулар һәм тирьяк турындагы бүлекләр төшерелеп калдырылган. «Гөлзар вә чәмәнзар»да Россия территориясендә үсә торган 192 үсемлекнең үзлекләре тасвирлана. К.Насыйри үзе чыгарган календарь битләрендә дә ботаникага караган төрле мәгълүмат бастыра, мәсәлән, 1888 елгы календаренда 313 төрле дару үләненең гарәп, татар, фарсы, латин һәм рус телләрендәге исемлеген урнаштыра. К.Насыйри үзенең хезмәтләре белән ботаника фәне үсешенә һәм татарлар арасында үсемлекләр турындагы белемнәрнең таралышына бил-

геле бер өлеш кертә. Шулай ук кара: *Медицина*.


Чыг.: Насыйри К. Хәвасе нәбатат. Казан, 1886; шул ук. Өч йөз йитмешләп дәва үләннәренең исемнәре русча, латинча, мөселманча // Календарь 1888 нче елга. Казан, 1887; шул ук. Гөлзар вә чәмәнзар, яғьни үләнлек вә чәчәклек. Казан, 1894; 1903.

Әд.: Шәйхелисламов З. Энциклопедист-галимнең хезмәте // Насыйри К. Шифалы үләннәр. Хәвасе нәбатат. Казан, 1999.

Р.В.Шәйдуллин.

«БУШ ВАКЫ́Т», табигать кануннары турында фәнни мәгълүматлы парчалар җыентыгы; татар әдәбияты тарихында дидактик жанрда язылган беренче китап. Рус язучысы һәм педагогы К.Д.Ушинскийның (1823–1870) 1861 елда башлангыч сыйныф укучылары өчен язылган «Детский мир» («Балалар дөньясы») фәнни-популяр һәм әдәби-педагогик хрестоматиясе мәкаләләре Каюм Насыйри тарафыннан кыскартып тәрҗемә ителеп, үзгәртелеп, ярым сәнгатьчә алымнар белән эшләнә. Кайбер хезмәтләрдә 1860 елда басылган һәм күләме 12 биттән гыйбарәт булган «Буш вакыт» китабы да К.Насыйригa нисбәт ителә. Җыентыкның беренче басмасы «Буш вакытларда укырга сүзләр» исемендә 1867 елда Казанда дөнья күрә.

Басманың эчтәлеге төрле табигыять һәм техник фәннәр белән кызыксынган балаларга юнәлтелгән һәм аларның көндәлек хезмәттән бушаган вакытын файдалы итеп уздыру өчен тәкъдим ителгән. Укытучы буларак К.Насыйри балаларның, гомумән, кешеләрнең буш вакытларын нинди шөгыль белән уздырырга тиешлекләрен яхшы белгән. Хикәяләрендә җирнең магнит кыры, һава һәм аның сыйфатлары, җылылык үлчәве, су һәм аның хасиятләре, яңгыр, чык, кырау, кар, боз, кыш, яз, җәй, көз, балчык, кирпеч, ут ташы, пыяла, тоз, шикәр, күкерт, тимер, җиз, бакыр, алтын, күнә суы [терекөмеш], икмәк агачы, тәвә кошы, кит, болан турында бәян ителә. Кайбер табигый күренешләр физика, химия һәм башка табигать-техника законнары нигезендә аңлатыла. Аларда шулай ук һава насосы һәм һава шарының табигать-техника законнары нигезендә эшләве раслана. Һәр парчада диярлек табигать күренешләре гади



К.Насыйри. «Буш вакытларда укырга сүзләр». Казан, 1867.

көнкүреш әйберләре ярдәмендә исбатлана. Мәсәлән, җирнең магнитизмы (җирнең тарту көче) — тәгәрәп килгән тәгәрмәчнең коймага бәрелүе һәм өскә таба сикерүе, һаваның җәелүе — кайнап торган самовардан чыккан бу (пар), һаваның җисеме — су салынган тирән савыт һәм аңа батырылган буш стакан белән төшендерелә.

Әлеге хезмәт К.Насыйриның вафатыннан соң, 1909 елда кабат «Балалар көтепханәсе» сериясендә Н.М.Чижова ташбасмаханәсендә 5 кисәккә бүленеп, һәрберсе 32 шәр битле

аерым китаплар рәвешендә бастырыла. Соңрак парчаларның берникадәр өлеше К.Насыйриның 1945 елда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»енә кертелә.

Чыг.: Насыйри К. Буш вакытларда укырга сүзләр. Казан, 1867; шул ук. Буш вакыт. Казан, 1909. 1–5 нче җөзьәләр.

Әд.: Вазеева Ж. Каюм Насыйри һәм балалар әдәбияты // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Җәләй Л. «Буш вакыт» (Балалар көтепханәсе) // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945.

Р.Ф.Исламов.

В

ВАГЫЙЗОВ Сәләй Гатат улы (20.10.1908, Самара губернасының Богырыслан өязе Татар Байтуганы авылы – 05.10.2005, Татарстанның шәһәр тибындагы Арча посёлогы), педагог, уку-укыту әсбаплары авторы. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Кәюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1988). ТАССРның атказанган мәктәп укытучысы (1968). Бөек Ватан сугышында катнаша.

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, 1936–1970 елларда Арча педагогия училищесында татар теле һәм методикасын укыта (бүленеп, Бөек Ватан сугышында, 1955–1960 елларда — Арча район халык мәгарифе бүлеге методисты). 1960 еллар уртасыннан Р.Г.*Вәлитова* белән берлектә милли мәктәпнең башлангыч сыйныфларында татар телен укытуны камилләштерү юнәлешендә эшли. 1965 елда алар яңа «Әлифба» (2006 елда аның 42 нче басмасы дөнья күрә), 1–2 сыйныфлар өчен татар теле дәреслекләре, уку китаплары, укытучылар өчен уку-укыту әсбабы (1975–2000 елларда үзгәрешләр белән 5 тапкыр басыла), педагогия училищелары өчен дәреслекләр төзиләр. Р.Г.Вәлитова белән берлектә язылган «Башлангыч сыйныфларда татар телен укыту методикасы» китабы (беренче басмасы — 1975 елда, яңартылган басмалары 1993, 2000 елларда дөнья күрә) «Лингводидактиканың иң зур казанышы» буларак бәяләнә. Хезмәтләре үзләренең төгәллекләре, камиллекләре, эчтәлеге, сыйфаты белән аерылып торалар, татар теленең сүзлек байлыгын, мәгънәви һәм кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәтү һәм белем бирү белән беррәттән туган телгә мәхәббәт тәрбиялиләр. Алар бүгенге көндә дә үзләренең актуальлеген югалтмыйлар.



С.Г.Вагыйзов

Арча шәһәрендәге «Әлифба» музеенда (1999 елда ачыла) Вагыйзов һәм Вәлитованың эш тәжрибәсе күрсәтелгән экспозиция төзелә. 2016 елда туган авылында музей ачыла. Биредә күренекле педагогның шәхси әйберләре, хатлары, китаплары, фотосурәтләре урын ала. Вагыйзов һәм Вәлитоваларның педагогик һәм методик идеяләрен үстерү һәм иҗади мирасын саклау, традицион милли рухи-әхлакый кыйммәтләрне ныгыту, башлангыч гомуми белем бирүдә яңа технологияләр кертү максаты белән 2023 елда I Республикакүләм Вагыйзов укулары уздырыла.

1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, СССР Педагогия фәннәре академиясенең К.Д.Ушинский исемендәге медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Әлифба. Казан, 1965 (автордаш); Туган тел. Казан, 1969; Кызыклы грамматика. Казан, 1970; Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы. Казан, 1975; Матур язу дәресләре: Башлангыч мәктәп укучыларына каллиграфик күнекмәләр булдыру: Укытучылар өчен методик кулланма. Казан, 1999;

Әд.: Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана. Казан, 1994; Вагыйзов Сәләй Гататович. Казан, 1998.

Ф.Г.Камальтдинова.

ВАКЫТЛЫ́ МАТБУГА́Т, билгеле бер ешлык белән чыга торган язма чыганакларның мөстәкыйль төре; массакүләм мәгълүмат һәм пропаганданың төп чараларыннан берсе.

Анда билгеле бер иҗтимагый төркем мәнфәгатьләрен ачыклау, белдерү һәм яклау максатында замандашларга чынбарлыкның аеруча мөһим вакыйгалары һәм күренешләре турында хәбәр итү өчен билгеләнгән мәгълүмат теркәлә. Бер үк вакытта вакытлы матбугат төрле чыганакларны бастырып чыгару бурычын да башкара, шуның нәтиҗәсендә аларны озак вакыт дәвамында саклап калырга мөмкинчелек тудыра. Вакытлы басманың һәр нөсхәсе килеп чыгышы җәһәтендә төрле булган күп кенә материалларның органик бердәмлеген тәшкил итә. Бу мәгълүматларның формалары аерыла: бер яктан, матбугатның үзендә барлыкка килгән мәкалә, очерк, фельетон, күзәтү, репортаж, интервьюлар, икенче яктан, әдәби һәм фәнни-популяр әсәрләр, мемуарлар, документлар, рәсемнәр, фотографияләр һәм башка материаллар дөнья күрә.

Вакытлы матбугат барлыкка килгәнче яңалыклар кулъязма битләр ярдәмендә таратылганнар, алар аерым илләрдә төрлечә оешканнар. Беренче басма газеталар 17 йөз башында Европада (Германия, Австрия, Голландия, Бельгия, Дания) барлыкка килә. Россиядә беренче басма газета — 1702 елда Санкт-Петербургта дөнья күргән «Ведомости» газетасы. Рус һәм татар телләрендә «Казанские известия» газетасы чыгаруга рөхсәт алу өчен беренче уңышсыз омтылыш 1808 елда Казан университеты профессоры И.И.Запольский тарафыннан ясала. Газетаны 1809 елда рус телендә генә бастырырга рөхсәт итәләр. 1811 елдан Казанда — «Казанские известия», 1838 елдан «Казанские губернские ведомости» газеталары чыга башлый. Казан университетының көнчыгыш факультеты студенты М.Г.Никольский 1834 елда Казан уку-укыту округы попечителе М.Н.Мусин-Пушкинга «Бәхрел-әхбар» («Яңалыклар диңгезе») газетасын чыгарырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. Ул, университет профессоры А.Казимбәк ярдәменә дә карамастан, рөхсәт ала алмый.

19 йөзнең 60 нчы елларыннан башлап, туган телдә вакытлы матбугат чыгару өчен көрәшкә татарлар да кушыла, алар арасында Каюм Насыйри һәм ташбасмаханә хуҗасы Мөхәммәдвәли Яхин да була. Алар булачак «Таң йолдызы» газетасының программасы аша татар халкын ил, сәүдә һәм сәнәгать яңалыклары, чит ил хәбәрләре, тормыш өчен кирәкле төрле мәсьәләләргә караган мәгълүматлар, яңа гына дөнья күргән тарихи, этнографик, әдәби әсәрләр һәм Россия законнары белән таныштырып торуны күздә тоталар. 1863 елда Насыйри һәм Яхин Казанның хәрби губернаторы П.Ф.Козлянинов исеменә татар телендә «Таң йолдызы» газетасын бастыруны сорап хат язалар. Әлеге хатта: «Татарлар сан ягыннан Россиядә руслардан кала икенче урында торсалар да, әлегә кадәр үзләренең вакытлы матбугаты юк. Шул сәбәпле хөкүмәт карарлары һәм яңалыклары татарлар тарафыннан ту-

рыдан-туры кабул ителә алмый, ә бәлки телдән-телгә күчә һәм шуның белән беренчел әһәмиятен югалта. Бу, үз чиратында, татарларның сәнәгать һәм сәүдә өлкәләрендәге яңалыклар белән вакытында танышмавына китерә. Ә мәгълүматның соңга калуы әлеге өлкәләрдә уңышлы эшләүче татарларга билгеле бер кыенлыклар тудыра. Моннан тыш, татарларның башка халык вәкилләре белән элемтәгә керергә теләмәүләрен дә исәпкә алсак, алар өчен яңалыкларны белү зарурлыгы аңлашыла. Барлык татарлар да рус телен белми, димәк, барысы да рус телендә газета укый алмый. Газетаны татар телендә чыгару югарыда санап үтелгән мәсьәләләрне хәл итәргә булышыр иде», — диелә. Козлянинов үз чиратында 1863 елның 28 августында бу хатны Россия Эчке эшләр министрлыгы каршындагы китап эшләре буенча совет карамагына җибәрә. Петербург цензура комитеты шушы совет исеменнән Казан губернаторына җибәргән җавабында, «яңа цензура уставы кабул ителмичә, газетаны басарга рөхсәт бирелә алмавын Яхин һәм Насыйровларга җиткерегез», — дип үтенечне кире кага. Әлеге вакыйгадан соң К.Насыйригa Казан руханилар семинариясендә укыган элекке укучысы Пётр *Масловский* ярдәмгә килә, ул бу мәсьәлә белән шәркыятьче галим, православие дине миссионеры Н.И.Ильминскийга мөрәҗәгать итә. Ләкин соңгысы аңа каршы килергә мәҗбүр була, чөнки аның рус булмаган халыкларны ана телләрендә укыту буенча эшчәнлеге тотрыклы булмый. Шуннан соң К.Насыйри вакытлы матбугат юнәлешендә эшчәнлеген еллык календарьлар чыгару рәвешендә башкарырга карар кыла. 1871 елдан башлап 24 ел дәвамында ел саен диярлек журнал рәвешендә эшләнгән «*Казан календаре*», «*Календарь*» исемле басмалар нәшир итә. Аларның эчтәлеге «Таң йолдызы» газетасы проектына якын була. Ул үзенең календарьлары белән татар вакытлы матбугатына ныклы нигез сала. 1905–1907 еллардагы революция чорында, Патшаның 1905 ел 17 октябрь Манифесты нигезендә матбугат иреге кабул ителгәннән соң, дистәләрчә татар газета-журналлары барлыкка килү моны ачык күрсәтә.

Әд.: Кәримуллин Ә. Каюм Насыйриның «Таң йолдызы» проекты // Казан утлары. 1975. № 2; шул ук. Тормышка ашмаган планнар // Казан утлары. 1970. № 7; шул ук. У истоков татарской книги: от начала возникновения до 60-х годов XIX века. Казань, 1971.

Р.В.Шәйдуллин.


«ВАСЫЯТЬНАМӘ», кешенең вафатыннан соң һичшиксез үтәлергә тиешле эш-гамәлләрне күрсәтеп, үзе исән вакытта үз кулы белән язган яки аның тарафыннан әйтелгәннәр язма рәвештә теркәлгән һәм шаһитлар имзалап расланган хокукый документ.

ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә Каюм Насыйриның 1899 елның 31 октябрендә үз кулы белән язылып, хосусый мөһере белән расланган бер васыятьнамәсе сакланa. Ул анда үзенең калачак акчаларын түбәндәгечә сарыф итәргә куша: 1) фидиягә 1000 сум 20 кешегә; 2) бер мәчет төзеттерергә 1000 сум; 3) җирләүгә һәм башка сәдакаларга 1000 сум. Васыятьне үтәүне Казан мещаны Бәдигъ Галим улы *Хөсәеновка* һәм Казан губернасының Зөя өязе Шырдан (хәзер *Кече Шырдан*) авылы кешесе Сәйфетдин Сөбханкол улына йөкләвен белдерә.

К.Насыйриның үз үтенече белән Казан губернасы Чабаксар өязе Әлмән авылы мулласы Габделкави та-

рафыннан 1902 елның 9 апрелендә язылган икенче васыятьнамәсе Казанда аның исемендәге музейда саклана. Үзенең 3500 сум акчасын, аңа китаплары һәм киемнәре бәясе булган 200 сумны кушып, гомуми 3700 сумны түбәндәгечә бүләргә куша: 1) үзен җирләү өчен 100 сум, аның 25 сумы мулла Йосыф Сәгыйтовка, 10 сумы мулла Галимҗан Галиевка; 2) фидия сәдакасына 600 сум, килешү буенча аның 100 сумы 10 шәкерткә, 200 сумы мәзин Бәдигъ Галим улына, 100 сумы Рафикъ Бәдигъ улына, 50 сумы Әлмән авылы мулласы Габделкави Габденнасыйр улына, 50 сумы Габделкави хатынына, 40 сумы Югары Шырдан авылы муллаларына һәм мәзиннәренә, 60 сумы ярлы туганнарына; 3) аның өчен хаҗ кылырга Мәккәгә кеше җибәрү өчен 400 сум. Бу эшне Рафикъ Бәдигъ улына йөкләргә, әгәр ул алынмаса, васыятьне үтәүче карамагына калдырырга. Васыятьне үтәүче итеп Казан мещаны мәзин Бәдигъ Галим улы Хөсәеновны билгеләгән, һәм соңгысы бу эшне башкаруны үз өстенә алган.

Васыятьнамәне төзегәндә обер офицер Хәмзә улы Дәүләтгәрәй Мамышев, Казан губернасының Казан өязе Түбән Әйшә авылы крестьяны Исмәгыйль Нәҗметдин улы Шәмсетдинов, Югары Шырдан авылы кешесе Сәйфетдин Сөбханколов, Зөя шәһәре мещаны Габделмән Габделхәй улы Казанский, Казанның 5 нче таш мәчет мулласы һәм ахун Мөхәммәтйосыф Сәгыйтов шаһит булганнар. Васыятьнамәнең губерна сәркатибе Ибнеямин Йосыф улы Аретьев тарафыннан рус теленә тәрҗемәсе шулай ук ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзә-


Насыри Каюм (Насыров Габделкаюм Габдельнасырович (1825-1902), татарский ученый, просветитель.

1902 апр. 9, Насыри Каюм
мая 7. Завещание, дополнение со слов автора на татарском языке муллой Ф. Альман Габдулкави Абдулнасыровым 9 апр. 1902г. Переведл на русский язык губ. секретарь Ибнеямин Иосифович Аретьев 7 мая 1902г. Подлинник на русском и татарском языках, арабский шрифт. Заверен нотариусом и печатью.

На 2 листах

Архив Казанского ... АН СССР
ОПИСЬ 11
ДЕЛО 3
ЛИСТ 18

Каюм Насыйриның 1902 елның 9 апрелендә язылган васыятьнамәсе.

гендә саклана. Ахырда документның 1902 елның 7 маенда 9938 нче номер белән расланыу турында нотариус Э.К.Михалковскийның аңлатма язуы бар, аның шәхси мөһере сугылган, имзасы куелган.

Чыг.: Каюм Насыйри васыятьнамәләренең төп нөсхәләре: ТӘҺСИ, 11 ф., 3 тасв., 13 сак. берәм.

Р.Ф.Исламов.

ВАХИ́ТОВ Рифкать Мөхәммәт улы (26.02.1938, Удмурт АССРның Ижевск шәһәре), нәкышьче, монументалист, портретчы, педагог. ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2005), ТРның халык рәссамы (2013), СССР (1972), Россия (1993), Татарстан Рәссамнәр берлекләре әгъзасы. Халыкара «Европа-Азия» академиясенең мөхбир әгъзасы.

Казан сынлы сәнгать училищесын (1959), Харьков сәнгать-сәнәгать институтын (Украина ССР, 1965) тәмамлый. 1970 елларда Үзбәкстанда Ташкент шәһәрендә яши: Театр-сәнгать институтында укыта, җәмәгать биналарын монументаль-декоратив бизәү («Динамо» стадионы фасадларында керәчтән мозаика, «Ташкент-2» аэропорты, «Ләззәт» кафесы фойеларына бизәк төшерү), нәкышь белән шөгыльләнә.

1973–1980 елларда Татарстанның Чаллы шәһәрендә «Татарстан» кунакханәсе фойесындагы «Сабан туе» керәч рельефлы панносын, автомеханика техникумындагы «Комсомол тарихы», 3 нче мәктәптәге «Тынычлык» мозаик панноларын иҗат итә. Аларда ул беренче тапкыр декоратив керәч плитка техникасы куллана. 1984 елдан Казанда эшли; 2006 елдан — Казан федераль университеты доценты.

Тарихи юнәлештә иҗат итүче рәссамның төп юнәлешләре — ислам сәнгате тарихы һәм татар халык иҗаты. Фантазиягә корылган картиналарында Болгар патшалыгы һәм Казан ханлыгы вакыйгаларын, исемнәре риваятьләргә кергән каһарманнарны, урта гасыр фаҗигаләрен, гади халыкның мәңгелек сагышын сурәтли. Ул шулай ук «Болгар иленә мәдхия» триптихы (1991), биш картинадан торган «Татарнамә» шәлкеме. (1995), «Моң» (1997), «Тукай дөньясы» полиптихы (2006), татар һәм Шәрекъ мөселман сәнгате традицияләрендәге пейзажлар, натюрмортлар авторы.



Р.М.Вахитов



Р.М.Вахитов.
«Каюм Насыйри» портреты. 2007.

Рәссамның милли традицияләргә таянып иҗат иткән портретлары арасында «Рәхимҗан бабай» (1980), «Гаяз Исхакый», «Бакый Урманче» (икесе дә — 1989), «Олуг Мөхәммәд» (2006), «Каюм Насыйри» (2007) әсәрләре бар. К.Насыйри портреты бөек мәгърифәтче турындагы истәлекләргә нигезләнеп языла. Анда ул энцик-

лопедист галим буларак сурәтләнә. Өстәлдә глобус, бите ачык китап, галимнең кулында зурайткыч пыяла, арткы фонда — китап тулы шкаф. Рәссам мәгърифәтченең фән өлкәсендәге киңкырлы эшчәнлеген күрсәтү белән берраттан аның киләчәк буынга биниһая зур мирас калдыруын да сурәтли.

Рәссамның эшләре музейларда, Татарстан, Россия һәм чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

Ф.Г.Камальтдинова.

ВӘЗИ́ЕВА Җамал Гали кызы (24.10.1907, Вятка губернасының Алабуга өязе (хәзер Әгерҗе районы Салагыш авылы) – 17.12.1989, Казан), әдәбият галиме, педагогика фәннәре кандидаты (1949).

Алабуга педагогия техникумын (1928), Казан педагогия институтын (1931) тәмамлый. 1931 елдан — Казан ветеринария, 1935 елдан Казан педагогия институтларында укыта.

Хезмәтләре 19–20 йөзләр татар әдәбияты тарихына, балалар әдәбиятына, татар әдәбиятын укыту методикасына карый. Аларда Каюм Насыйри әсәрләренә кадәр татар балалар әдәбиятында киң җәмәгатьчелеккә аңлашлы әдәби әсәрләрнең булмавын ассызыклый, мәгърифәтче галимнең күпкырлы әдәби һәм фәнни хезмәтләренең («Буш вакыт» (1860 елда 12 битле беренче варианты, 1867 елда 87 битле икенче варианты), «Кырык вәзир кыйссасы» (1868), «Әбугалисина» (1881), «Җәваһирел-хикәя» (хикәяләрнең җәүһәрләре) (1884), «Әхлак рисаләсе» (1890), «Тәрбия» (1891) һ.б.) балалар өчен, тәрбия темасына язылган өлешләрен анализый. Аның алдан күрүчәнлек сәләтен, нәсыйхәтләренең һәр заман өчен актуаль булуын, баланың аң-белеме, холкы формалашуда гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең



Ж.Г.Вәзиева

ни дәрәҗәдә әһәмияткә ия булуын билгеләп уза. Мәктәптә әдәбият укыту программасы һәм уку-укыту ярдәмлекләре авторларының берсе.

Почёт билгесе ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри — тәрбияче // Совет әдәбияты. 1945. № 2; Куәтсезлек вә курку күрсәтмә!... (Каюм Насыйри балалар турында) // Кызыл Татарстан. 1945; Татар әдәбияты. XX йөз (1917 нче елга кадәр): Дәреслек-хрестоматия. Казан, 1947 (автордаш); Каюм Насыйри һәм балалар әдәбияты // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Татар әдәбияты. XX йөз: Дәреслек-хрестоматия: 2 кис. Казан, 1954 (автордаш).

Әд.: Ибраһимова Ф. Укытучы бәхете // Азат хатын. 1987. № 10.

Ф.Г.Камальтдинова.

ВӘЛИДИ́ Җамал (Җамалетдин) Җәләлетдин улы (13.10.1887, Казан губернасының Тәтеш өязе Апас авылы – 30.11.1932, Карелия АССРның Медвежьегорск районы Медвежья Гора посёлогы), тел һәм әдәбият галиме, педагог, тарихчы, публицист, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе.

«Буби» мәдрәсәсендә (Вятка губернасының Сарапул өязе Иж Бубый авылы) укый. 1911–1918 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург шәһәре) белем бирә. 1918 елдан — Казанда: 1919 елдан мәктәпләрдә, Татар рабфагында, укытучылар әзерләү курсларында, Шәрекъ академиясендә укыта, бер үк вакытта ТАССРның Җир эшләре комиссариатында эшли, татар теле терминнарын эшләү ко-

миссиясен җитәкли. 1923–1931 елларда Шәрекъ педагогия институтында укыта.



Ж.Ж.Вәлиди

Хезмәтләрендә татар халкының иҗтимагый һәм милли үсеше мәсьәләләрен күтәрә, татар җәмгыятендә көнбатыш цивилизациясе казанышларын куллану юлларын өйрәнә, мөселман мәгарифе реформасын яклап чыга, татар әдәбияты үсешенең төп юнәлешләрен анализлый. Беренче чыгышларында ук үзен Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек ислахчылык һәм татар иҗтимагый фикерен яңарту тарафдары буларак күрсәтә, аларның фикерләренә таяна. Рус телендә иҗат ителгән «Татарларның укымышлылыгы һәм әдәбияты тарихыннан очерклар» («Очерки истории образованности и литературы татар», М., 1923) китабында борынгы заманнардан алып 1917 елга кадәрге чорда татар иҗтимагый фикере үсешенең төп баскычларын тасвирлый, 19–20 йөзләр татар фәне һәм мәдәнияте вәкилләренең эшчәнлегенә бәя бирә. Бу китабында автор Каюм Насыйри хезмәтләренең татар әдәби телен камилләштерүдә беренче тәҗрибә булуын, яңа әдәби телне нигезләвен һәм телгә карата кызыксыну уятуын таный; «Каюм Насыйри иң элек безнең татарлыгыбызны аңлады һәм аны үзенең әсәрләре илә башкаларга да аңлатмакчы булды», — дип яза. Аның татар теле грамматикасына, стилистикасына караган хезмәтләре һәм сүзлекләренең гаять әһәмиятле басмалар булуын икърар итә. «Каюм Насыйрида татар теле» мәкаләсендә (1922) галимнең татар теле үсешенә керткән өлешен ачык күрсәтә, шул ук вакытта аның күп кенә башка фәннәрне дә популярлаштыручы булуын ассызыклый.

«Татар теленең грамматикасы» (1919) исемле монографиясендә синтаксик категорияләрнең терминологиясен һәм системасын камилләштерә. Әлеге хезмәтне К.Насыйриның «*Әнмүзәҗ*»еннән (1895) соң татар теленең икенче фәнни грамматикасы дип карарга мөмкин. Татар теле диалектларына, башлыча, Нократ, Глазов, карин татарлары диалектларына багышланган хезмәтләре татар диалектологиясенең нигезе буларак бәяләнергә лаек. К.Насыйри үрнәгендә ул аерым татар милләтен, Казан татарлары диалекты нигезендә мөстәкыйль татар телен үстерүнең мөһимлеген ассызыклый. Милли әдәби тел төзү, аның язу системасын тәртипкә салу, әдәби нормалардан аерылыбрак торган диалектларны тәртипкә китерү, татар теленең мөмкин кадәр тулы грамматикасын язу, телнең тулы сүзлеген төзү мәсьәләләре белән шөгыльләнә, милләтне тәрбияләү, аның мәгарифен тәртипкә китерү, татар халкы тарихын булдыру буенча зур хезмәтләр яза. К.Насыйри кебек, 1927–1929 елларда «Татар теленең тулы сүзлеге»н төзи һәм басмага әзерли. Әлеге хезмәтнең А–Ә, У–Ү, Ы–Е, О–Ө, И һәм Б хәрефенең бер өлеше кергән беренче кисәге (352 бит) — 1927 елда, Б–П, Т хәрефләрен үз эченә алган икенче кисәге (353–720 бит) 1929 елда дөнья күрә (сүзлек эшләнеп беткән булса да, тулысынча басылмый кала). Анда хәзерге тюркология өчен дә әһәмиятен югалтмаган лексикографик принциплар беренче тапкыр кулланыла.

Әдәбият тәнкыйтьчесе буларак та таныла. Габдулла Тукай, Гаяз Исха-

кый, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал һ.б.ның иҗаты турында әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы.

1931 елда репрессияләнә, Ак диңгез каналы төзелешендә вафат була; үлгәннән соң аклана.

2001 елда әдәби тәнкыйть өлкәсендәге казанышлар өчен ТР Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе булдырыла.

Хезм.: Татар әдәбияты барышы. Оренбург, 1912; Милләт вә миллият. Оренбург, 1914; Шәрекътән Гаребкә // Аң. 1916. № 2–3; Татар теленең кагыйдәләре. Казан, 1918; Каюм Насыйрида татар теле // Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Татар телен эшләү мәсьәләсе // Безнең юл. 1924. № 4; Татар теленең тулы сүзлеге / Полный словарь татарского языка. 1 т. 1 нче кис. (А–Ә, У–Ү, Ы–Е, О–Ө, И, Б). Казан, 1927; Татар теленең тулы сүзлеге / Полный словарь татарского языка. 1 т. 2 нче кис. (Б-П, Т). Казан, 1929; Очерки истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.-П., 1923; О диалектах казанского татарского языка. Казань, 1927.

Әд.: Мөхәммәдиев Р. Югалмас мирас эзеннән // Казан утлары. 1977. № 9; Камалов Т. Джамал Валиди // Исторические портреты. Казань, 2000; Мухамадиев М.Г. Лингвистическое наследие Джамала Валиди // Татарская лексика в семантико-грамматическом аспекте. Казань, 1988; Татарские интеллектуалы: исторические портреты. Казань, 2005.

Ф.Г.Камальтдинова.

ВӘЛИ́ТОВА Рәмзия Гыйлаҗ кызы (29.03.1914, Уфа губернасының Эстәрлетамак шәһәре – 22.10.2002, Татарстанның шәһәр тибындагы Арча посёлогы), педагог, уку-укыту әсбаплары авторы; ТАССРның атказанган мәктәп укытучысы (1961), СССРның Халык мәгарифе отличнигы. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1988).



Р.Г.Вәлитова

Башкортстан АССР Эстәрлетамак педагогия техникумын (1931), Казан педагогия институтын (1937) тәмамлый. 1931–1933 елларда Башкортстан башлангыч мәктәпләрендә эшли. 1969 елга кадәр Арча педагогия училищесында татар теле һәм әдәбияты, татар теле методикасы укыта.

Хезмәтләре татар мәктәбенең башлангыч сыйныфларында татар теле укыту методикасына, аны камилләштерүгә карый; татар әлифбалары, шул исәптән 1965–2006 елларда 42 тапкыр басылып чыккан «Әлифба» автордашы (С.Г.*Вагыйзов* белән берлектә). Аның С.Вагыйзов белән берлектә язылган «Башлангыч сыйныфта татар телен укыту методикасы» дәреслеге «Лингводидактиканың иң зур казанышы» буларак бәяләнә.

1999 елда Вагыйзов һәм Вәлитова төзегән «Әлифба» дәреслегенә, аларның педагогик эшчәнлегенә нигезләнеп, шәһәр тибындагы Арча посёлогында (хәзер шәһәр) «Әлифба» музее ачыла.

Медальләр, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Хезм.: Әлифба. Казан, 1965 (автордаш); Әлифбага методик кулланма. Казан, 1966; Туган тел. Казан, 1969; Татар теле. Казан, 1982; Уку һәм язу китабы. Казан, 1986; Татар теле буенча дидактик материаллар. Казан, 1997.

Әд.: Ибраһимов Ф.И. Белем әлифбадан башлана. Казан, 1994.

Ф.Г.Камальтдинова.

ВӘЛИУ́ЛЛИН Мәҗит Әгъли улы (24.07.1941, ТАССРның Саба районы Йосыф-Алан авылы), укытучы, журналист; ТАССРның һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (1988, 2003). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2008).

Казан педагогия институтын тәмамлый (1967). 1961 елдан — Казан мәктәпләрендә укытучы; 1967 елдан — «Яшь ленинчы» газетасында, 1975 елдан — бүлек мөдире; 1977 елдан — «Совет мәктәбе» (хәзер «Мәгариф») журналында педагогика һәм методика бүлеге мөхәррире, 1986–1987 елларда — җаваплы сәркатип, 1987 елдан баш мөхәррир урынбасары булып эшли.

Очерклары һәм мәкаләләре «Ватаным Татарстан», «Советская Татария» газеталарында, «Азат хатын», «Ялкын» журналларында басыла. Язмаларында РФ һәм ТРда мәгариф системасының үсеш юлларын, яшь буынны укыту һәм әхлак тәрбиясе бирү мәсьәләләрен яктырта.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү. Казан, 1988; Без — Ильич оныклары. Казан, 1990; 3 нче класста татар теле дәресләре. Казан, 1999 (автордаш).

Ф.Г.Камальтдинова.

ВӘЛИУ́ЛЛИН Фәрит Рәшит улы (24.02.1959, Казан), педагог, рәссам, нәкышьче, монументалист, мозаика остасы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2014), ТРның халык рәссамы (2021), ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Татарстан (1971), Россия (1992) Рәссамнар берлеге әгъзасы, ТР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы (2001–2005).



Ф.Р.Вәлиуллин

Казан сәнгать училищесын (1978, Б.И.Майоров, В.И.Куделькин, З.Ф.Гыймаев классы), В.И.Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтын (1986, профессор Ю.К.Королёв курсы) тәмамлый. 1986 елдан Түбән Кама сәнгать фондында рәссам-монументалист, 1987 дән рәссамнарның Түбән Кама шәһәр иҗат төркеме рәисе булып эшли. 1989 елда Татарстанда «Гадел» шәхси сәнгать галереясын оештыручыларның берсе. 1998 елдан Яшел Үзән шәһәрендә. 2002 елда Яшел Үзән сәнгать галереясын оештыруда катнаша.

2006 елдан — Татар гуманитар-педагогика университетының, 2011 елдан – Казан федераль университетының рәсем сәнгате һәм дизайн факультетында рәсем укытучысы, хәзерге вакытта — Филология һәм мәдәни багланышлар институтының дизайн һәм милли сәнгать кафедрасы доценты.

Портрет, пейзаж, натюрморт, монументаль сәнгать жанрларында эшли. Түбән Камада Әфганстанда һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл, Түбән Кама үзәк хастаханәсе каршындагы Габдулла Тукай һәйкәле комплексларының авторы. Кол Шәриф мәчете гөмбәзенең эчке бизәлешен, Яшел Үзән җамигъ мәчете фасадын, Казан тимер юл вокзалы фасадын («Татар кызы», 2005) үзгәртеп кору ижади төркемнәре җитәкчесе.

Монументалист буларак, Вәлиуллин еш кына күләмле мәдәни, тарихи, фәлсәфи, темаларга мөрәҗәгать итә. Ул бу темаларны өйрәнеп, фикерен

детальләр аша югары дәрәҗәдә чагылдыруга ирешә. Әлеге сәләте аңа Болгар шәһәрендә Болгар цивилизацисе музеен бизәүдә катлаулы мәсьәләләрне хәл итүгә мөмкинлек бирә. «Болгарларның исламны кабул итүе» мозаика панносын (2х6 м) иҗат иткән төркем җитәкчесе. Бу хезмәткә керешү алдыннан рәссам тарихи документларга, аерым алганда Әхмәд ибне Фазланның Идел буена – Болгарга сәяхәте вакытында калдырган тәфсилле язмаларына мөрәҗәгать итә.

Картиналары: «Кич», «Сыер белән хатын-кыз», «Йөк тартучы үсмер», «Печән өсте», «Кара пулат төш күрә», «Сарык йоны кырку», «Бию», «Сөембикә һәм Үтәмешгәрәй», «Гаилә» (1994), «Бәләкәй Тукай», «Каюм Насыйри» (1991) һ.б.



Ф.Р.Вәлиуллин «Каюм Насыйри» портреты. Кәгазь, ретушь. 1991.

«Каюм Насыйри» портреты – график ысул белән иҗат ителгән әсәр. Автор мәгърифәтченең фоторәсеме булмаганлыктан, аны язганда башка рәссамнәр кебек үк тарихи чыганакларга мөрәҗәгать итә. Әдипне үткен карашлы, үз фикерләренә тугрылыклы, белемле һәм зирәк шәхес булуын ассызыклый. Күпчелек рәссамнарның әсәрләрендәгечә, галим кырпулы бүрек, утыртма якалы күлмәктән, җыйнак сакал-мыеклы итеп сурәтләнә.

РФ Дәүләт Думасында (2002), ТР Дәүләт Советында (2000, 2001) шәхси күргәзмәләр оештыра. Союзкүләм, республика, төбәк күргәзмәләрендә актив катнаша.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», РФ Рәссамнар берлегенең «Рухият. Традицияләр. Осталык» көмеш медальләре белән бүләкләнә.

Әд.: Гайнанова Г.А., Максютова Г.Р. Фарит Валиуллин: «Художники — это провидцы, они ближе к Богу...» // Идель. 2004. №8 (180); Султанова Р.Р. Валиуллин Фарит Рашидович // Искусство новых городов Татарстана (1960–1990 гг.): живопись, графика, монументально-декоративное искусство, скульптура. Казань, 2001.

Ф.Г.Камальтдинова.


ВОРОБЬЁВ Николай Иосифович (15.11.1894, Саратов губернасының Хвалынск шәһәре – 29.09.1967, Казан), этнограф, географ, тарихчы, тарих фәннәре докторы (1946), профессор (1935). ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1945), Бөтенсоюз география җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1964).

Казан университетының география факультетын тәмамлаганнан соң (1918), шунда ук ассистент булып эшли. 1918, 1920 елларда — Көнчыгыш Себердә этнографик командировкаларда: Түбән Енисей районында яшәгән җирле халыкларның тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен һәм шөгыльләрен өйрәнә. 1922 елдан — ТАССР Дәүләт музеенең этнография һәм табигыять-тарих бүлекләре мөдире, 1923 елдан — музей директоры. 1923 елдан — Көнчыгыш педагогия институтының география кафедрасы доценты, шул ук елдан — кафедра мөдире һәм география бүлеге җитәкчесе. 1934–1944 елларда — Казан педагогия инс-

титутының география факультеты деканы, бер үк вакытта Казан университеты профессоры. 1944 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры урынбасары, археология һәм этнография секторы мөдире.

Татарларның һәм чуашларның тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, Идел буе географиясен өйрәнүгә һәм пропагандалауга зур өлеш кертә. Татарстанның Арча, Зөя, Спас, Тәтеш, Чистай һәм башка кантоннарында татар халкының рухи һәм матди көнкүрешен өйрәнә. Җыелган материаллар нигезендә «Казан татарлары» китабын һәм башка хезмәтләрен нәшер итә. Шул фәнни тикшеренү-эзләнүләр барышында галим Каюм Насыйриның тарихи-этнографик хезмәтләре белән таныша һәм аларны үзенең эшчәнлегендә файдалана. 1945 елда К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессиядә ясаган «Каюм Насыйри — этнограф» исемле докладында мәгърифәтче галимнең 1896 елда «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә дөнья күргән «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)», 1900 елда П.А.*Поляков* белән автордашлыкта бастырган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» һәм 1880 елда «Император Рус география җәмгыяте язмалары»нда нәшер ителгән «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» хезмәтләрен фәнни күзлектән тикшерә һәм бәяли. Шулай ук «Каюм Насыйриның басылмаган әсәрләре»нең 1925 елда чыккан беренче томындагы этнография бүлеге материалларын да өйрәнә.

1948 елда татар һәм рус телләрендә дөнья күргән мәкаләләрендә К.Насыйриның беренче буларак үз халкының дөньяга карашын яктыртуы, галимнәргә шул вакытка кадәр тикшерелмәгән өлкәне ачуы ассызыклана, татар халкы тормышында үткәндә булып узганнарның, халыкның язмышына туры килгән социаль-икътисади формацияләрнең күп якларын аңларга ярдәм итүе белән аның «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» мәкаләсе этнография буенча бастырып чыгарган хезмәтләреннән иң кыйммәтлесе буларак бәяләнә. «Этнография мәсьәләләре белән өстән генә шөгыльләнгән булуына да карамастан, бу материаллар К.Насыйриның башка хезмәтләре арасында кыйммәтле материаллар булып торалар. Иң элек бу материаллар татар халкының үз вәкиле тарафыннан җыелган һәм фәнни мираска әверелгән беренче материаллар иделәр. Икенчедән, алар дөрес җыелган иделәр. Этнографик материалларны җыйган вакытта, җыючы шул халыкның үз вәкиле булмаса бигрәк тә, гадәттә күзәтү һәм сорашып белү ысуллары кулланыла. Күзәтү ысулы, көнкүрешнең тышкы күренешен өйрәнү ноктасыннан караганда, бик яхшы нәтиҗәләр бирә, бу ысулны кулланганда читтән күзәтүче кайчагында шул халыкның үз вәкиле сизә алмаслык вак детальләрне дә сизә... К.Насыйри материаллар җыя белү эшен туктаусыз мөкәммәлләштерә бара. Ул бу эштә өйрәнчек кенә түгел, аларны үз дөреслекләренә тәмам ышанганнан соң гына игълан итә бара. Үзенең «Поверья и суеверья» («Казан татарларының ышанулары һәм йолалары») мәкаләсенә керештә ул: «Укучыларны мин күп



Н.И.Воробьёв

еллар буена бу көнкүрешне күзәтүләрем һәм тикшеренүләремнең нәтиҗәләре белән таныштырам», — ди. Үзенең тикшеренүләрен ул аларны игълан итүдән бик күп элек башлый, аларны тәҗрибәле галимнәргә бәяләмәгә җибәрә. Мәсәлән, ИРГОның (Император Рус география җәмгыяте) этнография бүлеге тарафыннан аның материалларын бастыру турында 1868 елда язылган хаты бар: «Хәлбуки аның бу хезмәте ахыргы редакциясендә 1880 елда гына басылып чыккан. К.Насыйри, үзенең хезмәтенә зур җаваплылык белән карап, аны тагын бер тапкыр тикшереп чыккан һәм өстәмә мәгълүматлар белән баеткан. Тулы вөҗданлылык белән эш итүе һәм дөреслегендә шик булмаган материалларны гына җыюы К.Насыйриның этнография өлкәсендәге хезмәтләренең төп кыйммәте булып тора», — дип яза; үз халкы өчен күп эшләгән, беренче буларак рус мәдәниятен дә үз халкының бай көнкүреше белән таныштырган һәм аны ул заманда нинди төстә булса, нәкъ шул рәвештә күрсәткән, дип нәтиҗә ясый.

Ленин ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри — этнограф // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Казанские татары. Казань, 1953; Материальная культура казанских татар. Казань, 1930; Поволжские татары // Народы мира. М., 1964.

Әд.: Бусыгин Е.П., Зорин Н.В. Николай Иосифович Воробьев. 1894–1964. Казань, 2002.

И.Х.Хәлиуллин.

«ВЫДАЮ́ЩИЙСЯ ПРОСВЕТИ́ТЕЛЬ-ДЕМОКРА́Т КАЮ́М НАСЫРИ́» («Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри»), фәнни доклад-

лар җыентыгы. 1975 елның 11–12 февралендә Казанда Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулу уңае белән уздырылган тантаналы утырыш һәм фәнни конференция материалларын үз эченә ала. 1976 елда дөнья күрә. Җыентыкның җаваплы мөхәррире — Я.Г.*Абдуллин*, редакция коллегиясе әгъзалары — А.Н.Кононов, М.К.*Мөхәррәмов*, М.Х.*Гайнуллин*, Ф.С.*Фасиев*, Х.Ш.*Мәхмүтов*.

Фәнни конференциядә Мәскәү, Татарстан, Дагстан галимнәре һәм сәясәт эшлеклеләре докладлар белән чыгыш ясыйлар, чыгышларның күпчелеге әлеге җыентыкка кертелә. КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М.Ф.Вәлиевнең «Татар мәдәнияте горурлыгы» мәкаләсендә К.Насыйриның күпкырлы фәнни эшчәнлеге ассызыклана, галимнең татар халкын мәгърифәтле итүдәге, татар мәдәниятен үстерүдәге, халыклар дуслыгы идеяләрен пропагандалаудагы казанышлары югары бәяләнә. Профессор М.К.Мөхәррәмовның «Каюм Насыйри һәм ул яшәгән чор» мәкаләсендә галим яшәгән чор тулы яктыртыла, мәгърифәтче үзе татар демократик мәдәниятенә нигез салучыларның берсе буларак тасвирлана. Профессор К.Ф.Фасиевнең «Халыклар дуслыгы җырчысы» һәм Я.Г.Абдуллинның «Татар иҗтимагый фикере тарихында Каюм Насыйриның урыны» дип аталган мәкаләләрендә К.Насыйриның иҗтимагый һәм фәлсәфи карашлары, татарлар, руслар һәм башка халыклар белән дуслык-арадашлык мөнәсәбәтләрен ныгытудагы роле яктыртыла.

Профессор М.Х.Гайнуллинның «Атаклы татар галиме һәм язучысы», филология фәннәре кандидатлары Ә.Г.*Кәримуллинның* «Каюм Насыйриның наширлек эшчәнлеге һәм «Таң йолдызы» газетасы проекты», М.В.*Гай-*

нетдиновның «XIX гасыр әдәби хәрәкәте һәм Каюм Насыйри» дип исемләнгән мәкаләләрендә мәгърифәтче галимнең 19 йөздә татарлар арасындагы әдәби хәрәкәт үсешенә йогынтысы, аның әдәби-наширлек эшчәнлеге чагылыш таба.

Академик А.Н.Кононовның «Татар тел белеме тарихыннан: Иосиф Гигановның татар грамматикасы (1801 ел)», профессорлар М.З.*Зәкиевнең* «К.Насыйри һәм хәзерге татар милли теле



Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри. Казан, 1976.

формалашу», В.Х.*Хаковның* «Татар тел белемендә К.Насыйри традицияләре», филология фәннәре кандидатлары Ш.С.*Ханбиковаңың* «Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге», Ф.С.Фасиевнең «Насыйри һәм татар терминологиясе», И.Г.*Абдуллинның* «Татар әдәби телен демократияләштерү һәм үстерүдә Каюм Насыйриның роле», фәнни хезмәткәр Я.С.*Әхмәтгалиеваның* «Каюм Насыйри һәм татар грамматикасы» мәкаләләрендә К.Насыйриның тел белеме өлкәсендәге эшчәнлегенең төрле аспектлары һәм аңа кадәр Россиядә татар тел белеме үсеше этапларының берсе тикшерелә.

Тарих фәннәре кандидатлары С.М.*Михайлованың* «Каюм Насыйри һәм Казан университетында шәркыять гыйлеме», Р.Г.*Фәхретдиновның* «Каюм Насыйриның Казан татарлары тарихына һәм археологиясенә керткән өлеше», Р.К.Уразмановаңың «Этнограф буларак Каюм Насыйри», филология фәннәре кандидаты Х.Ш.Мәхмүтовның «Каюм Насыйриның татар фольклористикасы тарихындагы урыны», медицина фәннәре кандидаты Р.М.Шәрәфетдинова белән фәнни хезмәткәр Ә.Н.*Хәйруллинның* автордашлыкта язылган «К.Насыйриның этнографик хезмәтләрендә халык медицинасы мәсьәләләре» дип аталган мәкаләләрендә мәгърифәтче галимнең тарих, археология, этнография, фольклор өлкәсендәге фәнни казанышлары, аның татар халкы арасында медицина гыйлемен таратудагы эшчәнлеге яктыртыла.

Филология фәннәре кандидаты С.Х.*Акбиевның* «Каюм Насыри и Абусуфьян Акаев» исемле мәкаләсендә Каюм Насыйриның кумык мәгърифәтчесе, шагыйрь, илаһият галиме, нашир Әбусуфьян *Акаевның* ижтимагый-педагогик эшчәнлегенә йогынтысы, тарих фәннәре кандидаты С.Х.*Алишевның* «Каюм Насыри и Мухаметзян Аитов», Ә.Н.Хәйруллинның «Насыри и Марджани» мәкаләләрендә мәгърифәтче галимнең замандаш галимнәре һәм үзенең шәкертләре белән мөнәсәбәтләре бәян ителә.

К.Насыйриның фәнни-педагогик эчәнлеге педагогия фәннәре кандидатлары А.Ш.*Әсәдуллинның* «Каюм Насыйри рус телен өйрәнү турында», Х.Х.Хәкимовның «Беренче татар дөньяви мәктәпләрен оештыручылар» мәкаләләрендә чагылыш таба.

К.Насыйриның ТАССР Дәүләт музеенда саклана торган фонды турында әдәбият бүлеге мөдире Д.Б.*Баһаветдинованың* «ТАССР Дәүләт музеенда Каюм Насыйри фонды» мәкаләсеннән тулы мәгълүмат алырга мөмкин. Фәнни хезмәткәр Р.М.*Әмирхановның* «Каюм Насыйриның 150 еллыгына багышланган чаралар» мәкаләсендә галимнең тууына 150 ел тулу уңаеннан Казанда, Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылында үткәрелгән фәнни конференцияләр, концертлар турында тәфсилле бәян ителә.

Чыг.: Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Әд.: Амирханов Р.М. Мероприятия, посвященные 150-летию со дня рождения Каюма Насыри // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Р.Ф.Исламов.

Г

ГАБДЕЛГАНИ́ЕВА (Әбделганиева) Мәдинә Хәниф кызы (05.09.1945, Татарстанның Беренче Май (хәзер Чирмешән) районы Югары Чагадай авылы), филолог, педагог, ТРның атказанган укытучысы (2001), РФнең Халык мәгарифе отличнигы (1995), ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1989).

Казан педагогия институты тарих-филология факультетының рус теле бүлеген тәмамлаганнан соң, 1968–1969 елларда Чирмешән районы Югары Чагадай сигезьеллык мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1969–1974 елларда — Мурманск, 1975–1980 елларда — Кырым өлкәләрендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы, 1981–1983 елларда — Сызрань шәһәрендә педагог-оештыручы. 1983–1985 елларда — Казан шәһәренең 23 нче мәктәбендә тәрбияче, аннан соң 1989 елга кадәр — татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 1989–2001 елларда – 103 нче урта мәктәптә милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары.

Татар мәгърифәтчеләре Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Бигиевнең хезмәтләрен өйрәнә. К.Насыйриның әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышланган иң мәшһүр әсәрләрен үзенең педагогик эшчәнлегендә киң куллана. Аның «Китап әт-тәрбия» китабының актуальлеген, ул биргән үгет-нәсыйхәтләр, киңәшләрнең ата-аналарга, укытучылар һәм тәрбиячеләргә генә түгел, һәр балага да кызыклы һәм файдалы булуын, гыйлем өйрәтүнең әһәмиятен аңлап эш итә. Туган авылы тарихына караган мәгълүматларны, авыл халкының нәсел шәҗәрәләрен иске имлядан тәрҗемә кыла, дини календарьлар чыгара һәм китаплар яза.



М.Х.Габделганиева

«ТАССР төзелүгә 100 ел» медале белән бүләкләнә. Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен ТР Президентының Рәхмәт хатына лаек була. Мөхлисә Буби исемендәге бүләк иясе (2015).

Хезм.: Җиде буын җылысы // Мәгариф. 1999. № 2 (автордаш); Вәлиев Х. Югары Чагадай мирасы / төз. М.Х.Габделганиева. Казан, 2015; Ислам и мусульмане в русской литературе / сост. М.Х.Абдулганиева. Казань, 2006; С небесной книги список дан: Исламские мотивы в русской литературе XV–XXI веков: сборник / сост. М.Х.Абдулганиева. Казань, 2021.

Әд.: Максютова Г. Судьба наставила их на этот путь // Республика Татарстан. 2003. 15 мая; Яхина Р. Изгелек // Шәһри Казан. 2000. 29 март.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ГАБДУ́ЛЛИН Габделхан Габдулла улы (05.07.1936, ТАССРның Ма-

мадыш районы Сәртек авылы), педагог, педагогика фәннәре докторы (1991), профессор (1991). РФнең атказанган мәктәп укытучысы (1991), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1994). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2007).



Г.Г.Габдуллин

Казан университетын тәмамлый (1967). 1958–1967 елларда — комсомол һәм партия эшендә, 1964 елдан — КПССның Әгерҗе райкомы секретаре. 1967–1970 елларда — Әгерҗе урта мәктәбендә: тарих укытучысы, мәктәп директоры. 1970–1979 елларда — Әгерҗе районы халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1979–1984 елларда — ТАССР мәгариф министры урынбасары. 1984 елдан — Казан педагогия университетында, 1988 елдан — педагогика кафедрасы мөдире, бер үк вакытта проректор (1990–1995).

Хезмәтләре мәктәп, мәгариф системасында идарә итүгә, уку-укыту өлкәсендәге социаль проблемаларга карый. 100 дән артык фәнни хезмәте, шул исәптән «Мәктәпне үзгәртеп кору: идарә проблемалары», «Мәктәп белән идарә итүнең программ-максатчан ысулы» монографияләре бар.

Медаль, ТРның Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Хезм.: Перестройка школы: проблемы управления. Казань, 1990; Педагогика школы. Казань, 1993; Школоведение. Казань, 1997; Воспитательный потенциал педагогических дисциплин в формировании личности будущего учителя. Казан, 2003 (автордаш).

Ф.С.Гыйниятуллина.

ГАБИДУ́ЛЛИН Хажи Заһидулла улы (1897, Уфа губернасының Бәләбәй өязе Сәвәдебаш авылы – 12.08.1940), дәүләт эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты (1933), профессор (1934).

Көнгер тимер юл училищесын (1911), Кызыл профессорлар институтын (1933) тәмамлый. 1916 елдан — Россия армиясендә. Төмән губернасында 1917 елгы Октябрь кораллы күтәрелешендә катнаша. 1917–1918 елларда — мөселман эшләре буенча комиссар. 1919 елда — 11 нче Петроград дивизиясенең кавалерия полкы, аннары бригадасы хәрби комиссары. 1920 елда — Казан кавалерия курслары комиссары. 1920–1924 елларда — ТАССР Милиция баш идарәсе җитәкчесе, 1924–1927 елларда ТАССР Халык Комиссарлары Советы рәисе. 1927–1930 елларда — РСФСРның Кече Халык Комиссарлары Советы әгъзасы. 1933–1937 елларда — РСФСР Университетлары һәм фәнни-тикшеренү оешмалары баш идарәсе җитәкчесе, бер үк вакытта Мәскәү университетында колониаль һәм бәйле илләр тарихы кафедрасы мөдире. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

Хезмәтләре Россиядәге пантюркизм һәм панисламизм тарихына, төрек буржуаз революциясе вакыйгаларына карый. Татарстан җөмһүриятенең Халык Комиссарлары Советы рәисе буларак, Х.Габидуллин Каюм Насыйриның 100 еллыгына багышланган җыелышта чыгыш ясарга тиеш була, ләкин кичектергесез эшләр килеп чыгу сәбәпле катнаша алмый. Аның котлау хатында Насыйриның зирәк акыл иясе, күренекле мәгърифәтче, татар халкы тарихына зур өлеш керткән, чын дәрәҗәдә милли энциклопедик галим булуы билгеләп үтелә; 100 еллыгы уңаеннан әлеге чараны олылап үткәрүнең, галимнең әсәрләрен бастыру, тор-

мышы, иҗаты, хезмәте турында тулы мәгълүмат бирерлек җыентыклар чыгаруның, исемен мәңгеләштерүнең әһәмияте ассызыклана.



Х.З.Ғабидуллин

Хезм.: Татарстан за семь лет (1920–1927). Казань, 1927; Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М., 1931 (автордаш); Младотурецкая революция. М., 1936.

Ф.С.Ғыйниятуллина.

ГАИЛӘ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ́, аерым затлар арасында кардәшлеккә, никахка, уллыкка (кызлыкка) алуга нигезләнгән мөнәсәбәтләр. Татарларда гаилә мөнәсәбәтләренә милли гореф-гадәтләр һәм мөселман (керәшен татарларда — христиан) тәртипләре көчле йогынты ясаган, гаилә борынгы заманнардан ук тотрыклы хуҗалык итүнең бердәнбер мөмкин төре, җитеш картлыкның терәге булып торган, ә никахлашу исә табигый зарурлык саналган. Ата-ана һәм бала-чагадан гына торган кечкенә (19 йөз ахырында андый гаиләнең уртача составы 5–4 кешегә җиткән) яисә 3–4 буын якын туганнарны берләштергән ишле татар гаиләләре гомумгаилә милке нигезендә оешкан. Традицион гаилә этикетының төп принциплары балаларның — ата-ананы, кечеләрнең — өлкәннәрне берсүзсез хөрмәт итүе һәм олылавына нигезләнгән. Балаларны кече яшьтән үк эш белән тәрбияләгәннәр, һөнәргә өйрәткәннәр. Татарлар балаларын укырга-язарга өйрәтүне даими игътибар үзәгендә тоткканнар.

Каюм Насыйри хезмәтләрендә («*Әхлак рисаләсе*», «*Ғакаид рисаләсе*», «Китаб-әт-тәрбия», «*Кырык бакча*», «*Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият*» һ.б.) гаилә мөнәсәбәтләре (өлкән һәм кече буыннар, ир һәм хатын, ата-аналар һәм балалар, туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр, бала тәрбияләү һ.б.) мәсьәләләренә зур урын бирелә, гадәттә, алар әхлак яссылыгында карала, шәригать өйрәтмәләрендәгечә гәүдәләнгән изге хатын образының, аның үгет-нәсыйхәтенең әһәмияте, хезмәтнең тәрбияви роле тирәнтен яктыртыла. Мәгърифәтче галимнең төп педагогик принцибы — тәрбиядә халыкчанлык һәм гуманлылык. Ул балаларның тәрбияле, белемле һәм сәламәт булып үсүенә булышлык итүне иң изге эш дип саный, ничек булырга кирәклек турында вәгазь уку, үгетләүдән бигрәк, яманны һәм яхшыны, явызлыкны һәм тәүфикъылыкны, нәфесне һәм чик-чаманы белү, уртачалыкны янәшә куеп, чагыштырып төшенергә чакыра, гаиләдә ата-ана гамәлләренең күркәм мисалларына игътибарны юнәлтә. Шул вакытта К.Насыйри эти-әниләргә яшьләрдә туган илгә мәхәббәт, кыюлык, батырлык, тапкырлык, хезмәт сөючәнлек, дөреслек, тугрылык, күркәмлек кебек әхлак сыйфатларын тәрбияләргә киңәш итә. Л.Н.Зәйнетдинова, әдипнең«Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» әсәрендәге хикәятләрен анализлап, соңгыларының дөньяга караш җәһәтендә башлыча ислам фәлсәфәсен, шәригать өйрәтмәләрен гәүдәләндерүләре, хатын-кызларның ирләренә тугры булып, изге хатын булып яшәүләрен идеал итүләре хакында нәтиҗә чыгара, галимнең тискәре образлар аша тәрбия кылу алымына да мөрәҗәгать итүен, кайбер хикәятләрнең нигезендә «шундый булырга ярамый» дигән кинаяле нәсыйхәт ятуын ассызыклый. Шулай ук кара: *Балалар әдәбияты.*

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2003–2006.

Әд.: Абдуллин Я. Каюм Насыйри иҗатында мораль-этик мәсьәләләр // Казан утлары. 1975. № 2; Җәләлиев Ш. К.Насыйри иҗатында татар халык тәрбиясе // Мәгариф. 2001. № 6; шул ук. Милли тәрбия нигезләре: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре, педагогия колледжлары, училищелары өчен уку ярдәмлеге. Казан, 2003; Зәйнетдинова Л.Н. Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» әсәрендә әхлак һәм гаилә мөнәсәбәтләре // Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре. Казан, 2000. 1 чыг.; Лотфи Г. Каюм Насыйри — педагог (К.Насыйриның тууына 125 ел тулу уңае белән) // Совет мәктәбе. 1950. № 1; Ханбиков Я. Каюм Насыйри хезмәт тәрбиясе турында // Совет мәктәбе. 1962. № 9; Мусина Р.Н. Семья и семейный быт // Татары. М., 2001; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967.

И.Х.Хәлиуллин.

ГАЙНЕТДИ́НОВ Мәсгуд Вәлиәхмәт улы (25.05.1929, хәзерге Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районы Лабит авылы – 24.04.2016, Казан), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (2000).

Мәләкәс шәһәрендә Укытучылар институтын тәмамлый (1950). 1968 елга кадәр Үзбәкстан ССРның Яңа Юл районы урта мәктәпләрендә укыта. 1968 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1996–2003 елларда ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли. Каюм Насыйриның сайланма әсәрләрен (1957), Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен, Хәсән Туфанның сайланма әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә, «Татар поэзиясе антологиясе»н төзүдә катнаша, Х.Туфан иҗатын тирәнтен өйрәнә.



М.В.Гайнетдинов

Хезмәтләре 19–20 йөзләр татар әдәбияты тарихына, совет чоры поэзиясенә, татар әдәбияты текстологиясенә карый. К.Насыйри «Сайланма әсәрләр»енең 1, 2, 4 нче томнарын (2003–2006 елларда нәшер ителә) төзүче. Ул аның, гарәп графикасында сакланган текстларын гамәлдәге язуга күчереп, матбугатта дөнья күргән хезмәтләре белән беррәттән, моңа кадәр таныш булмаган әсәрләрен дә туплый. «XIX йөздә әдәби процесс һәм Каюм Насыйри» мәкаләсе авторы. 19 йөз Россия тарихында гомумән, татар иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында аерым алганда, зур үзгәрешләр чоры буларак характерлана. Үзенең киңкырлы эшчәнлеге белән танылган, бөтен тормышын, талантын үз халкын агартуга багышлаган, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкилләреннән берсе булган К.Насыйри милли рухлы тормыш мәйданына шул вакытларда чыга. М.Гайнетдинов мәгърифәтче әдипнең үз заманы әдәби хәрәкәте үзәгендә булуын, аның иҗатында 19 йөзнең 2 нче яртысы татар әдәбиятының актуаль проблемалары чагылыш табуын билгели; 19 йөздә зур кыйммәткә ия булган хезмәтләренә, хәзерге чорда да әһәмиятен югалтмаган «Әбугалисина», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» һәм башка әсәрләренә тирән анализ ясый, галимнең татар әдәбияты тарихына һәм шулай ук әдәбиятның башка тармакларына да зур өлеш кертүен, әдәбият тарихы өчен материаллар җыюга башлангыч бирүен яктырта.

Аның шулай ук Габделҗәббар Кандалыйның киң массага аңлаешлы татар телендә язуын үз итүен, шигырьләрен җыюын, шулай ук Габдерәхим Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави һәм башка татар мәдәнияте эшлеклеләренең иҗатларын, тормыш юлларын өйрәнүен югары бәяли.

Хезм.: Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1985. Т. 2 (автордаш); Давылларда-җилләрдә. Казан, 1989; Хакыйкать юлыннан. Казан, 2001; Литературный процесс XIX века и Каюм Насыри // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Әд.: Исламов Р. Бәрәкәтле хәрәкәт // Мәдәни җомга. 1999. 21 май.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ГАЙНУ́ЛЛИН Мөхәммәт Хәйрулла улы (18.08.1903, Казан губернасының Тәтеш өязе Коллар авылы (хәзер Татарстанның Апас районы Кызыл Тау авылы) – 24.05.1985, Казан), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1958), профессор (1967). ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1963, 1973).

Казан Шәрекъ педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1931), шунда ук эшли. 1943–1944 елларда — Татарстан дәүләт нәшрияты җитәкчесе, 1944 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1944–1953, 1959–1961 елларда директор). Габдулла Тукай, Каюм Насыйри, Шәриф Камал иҗатларына багышланган беренче мәкаләләре 1930 елларда басыла. 1950–1960 еллардагы хезмәтләрендә Закир Һади, Заһир Бигиев, Муса Акъегетзадә, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Шакир Мөхәммәдов иҗатларын анализлый. 20 йөз башы татар публицистикасын өйрәнә. Беренче татар хатын-кыз язучыларының (Газизә Сәмитова, Маһруй Мозаффария, Зәйнәп Сәгыйдә, Гыйффәт Туташ, Мәхбүбҗамал Акчурина) әсәрләрен туплаган «Өмет йолдызлары» (1988) җыентыгын төзүче һәм кереш сүз авторы.



М.Х.Гайнуллин

Төп хезмәтләре 19 йөз – 20 йөз башы татар әдәбияты, иҗтимагый фикер һәм матбугат тарихына карый. Ул шулай ук Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлеге турында шул заманның көндәлек матбугат битләреннән, архивлардан, замандашлары истәлекләреннән күпләгән яңа мәгълүматлар туплый һәм аларны фәнни әйләнешкә кертә. Үзенең хезмәтләрендә К.Насыйриның матур әдәбият өлкәсендә дә әһәмиятле урын биләвен һәм универсаль хезмәтләр авторы: бер яктан, тәрҗемәче һәм үзе дә оригиналь әсәрләр иҗат итүче, икенче яктан, әдәбият тарихчысы, фольклор җыеп, аны гыйльми нигездә тикшереп бастыручы һәм үзенә кадәр булган татар шагыйрьләренең әсәрләренә игътибар итеп, аларны фәнни яктан өйрәнә башлаган галим булуын ассызыклый. К.Насыйрига кадәр татар телендә киң җәмәгатьчелек файдаланырлык басма әдәби әсәрләр бик аз, булганнары да Истанбулда басылган әсәрләрне, хәтта телен дә татарчага үзгәртмәстән, яңадан нәшер итеп таратудан гыйбарәт була. К.Насыйри, фәнни һәм педагогик эшчәнлеге белән бергә, халык файдалана алырлык үз әдәби әсәрләрен бастырып таратуны бурыч итеп куя. Аның матур әдәбият өлкәсендәге беренче хезмәте — «Кырык вәзир кыйссасы» әсәре 1868 елда дөньяга чыга. Гомеренең соңгы елларына кадәр ул әдәби иҗаттан аерылмый.

Әдипнең татар телендә әдәби тәнкыйтьне нигезләү, үстерү буенча да хезмәтләре бар. Тәрҗемә өчен әсәрләр сайлаганда ул үзенең омтылышларына, теләкләренә җавап биргән әсәрләргә өстенлек бирә. Шундыйларның берсе — «Кабуснамә». К.Насыйри, фольклор материалларын җыю белән беррәттән, аларга карата теоретик карашларын да бәян итә. Әлеге материаллардан үз вакытында Н.Ф.*Катанов* һәм башка тюркологлар да файдаланалар. Катанов үзе дә «Казан татарларының тарихи җырлары» («Исторические песни казанских татар») китабындагы бәетләрне К.Насыйридан алганлыгын, бәетләрнең халык тарафыннан иҗат ителмичә, аерым кешеләр тарафыннан язылган булуын аның фикеренә таянып әйткәнлеген күрсәтеп яза. К.Насыйри халык арасында йөргән риваятьләрне, легендаларны җыеп туплауның, гыйльми яктан тикшереп чыгуның кыен, җитди һәм җаваплы гамәл булуын күз алдында тотып эш итә.

Каюм Насыйри — 19 йөз татар мәгърифәтчеләре арасында иң алдынгысы һәм иң эшлеклесе. Ул тел галиме генә түгел, киң колачлы универсаль фикер иясе һәм күренекле педагог та, татар халкын төрле фән нигезләре белән үз ана телендә беренче буларак таныштыручы да була. Аның кыю фикерләре, әдәби һәм фәнни хезмәтләре үз чорында җитәрлек дәрәҗәдә бәяләнмәгән, киресенчә, үзенә төрле сүзләр ишеттереп торганнар, әмма алар халыкның киләчәгенә нык ышанган ватанпәрвәр галим һәм язучыны иҗат эшеннән туктата алмаган. Гайнуллин «Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы)» язмасында бу хакыйкатьне ачык яктырта.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри // Совет әдәбияты. 1944. № 1; Каюм Насыйри документларда // Совет әдәбияты. 1945. № 2; Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Бөек мәгърифәтче һәм патриот // Совет әдәбияты. 1950. № 2; Мәгърифәтче, педагог Каюм Насыйриның үлүенә 50 ел // Совет мәктәбе. 1950. № 4; Каюм Насыйри: (Тормышы һәм иҗат юлы) // Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956. 2 нче басма; Каюм Насыйри (1825–1902) // Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1974. 1 т.; Татар әдипләре. Казан, 1978; Каюм Насыйри (1825–1902) // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Казан, 2015. 3 т.; Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань, 1966; Татарская литература XIX века. Казань, 1975; Видный татарский ученый и писатель // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Әд.: Мөхәммәт Гайнуллин — олуг галим һәм язучы. Казан, 2003.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ГА́ЙСИН Талип (1875, Казан губернасының Зөя өязе Югары Шырдан авылы (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы) – ?), колхозчы, Каюм Насыйри авылдашы һәм аның турында хатирә авторы.

Туган авылында крестьян тормышы белән көн күрә. К.Насыйри белән якыннан таныш була. 1945 елда фольклорчы Хәмит *Ярми* аннан галим турында истәлек язып ала. Гайсин үзенең хатирәсендә К.Насыйриның җәй көннәрендә Югары Шырдан авылына еш кайтуы, кайтканын ишеткәч, авыл малайларының аның капка төбенә җыелышуы, Каюм бабаларының матур биегән-җырлаган һәм кызык мәзәкләр сөйләгән, мәкальләр әйткән малайлар-

га берничә тиен акча бирүе хакында бәян итә. К.Насыйриның җәй көннәрендә болынга (кырга) чыгып үләннәр җыюын, халыкка китаплар өләшүен, Казаннан укытучыларга бүләкләр җибәрүен, авылда мәктәп салдыруын искә ала. Үзенең әлеге мәктәптә 1–2 ел гына укуын, ярлы баласы булгач, җәй көне көтү көтеп, кышларын исә, кияр киеме булмаганлыктан, сабакка йөри алмаганлыгын тәфсилләп сөйли. Аның истәлеге 1948 елда дөнья күргән «Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)» җыентыгында урнаштырыла. Шулай ук кара: *Истәлекләр.*

Әд.: Гайсин Т. Авылдашлары Каюм Насыйри турында // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык /төз. Р.Ф.Исламов. Казан, 2017.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ГАЙФУ́ЛЛИН Васил Габдулла улы (23.03.1937, Татарстанның Мөслим районы Югары Табын авылы), дәүләт эшлеклесе, педагог, педагогика фәннәре докторы (1990), профессор (1991). ТАССРның атказанган мәктәп укытучысы (1987), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2000), РФнең атказанган укытучысы (2004). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2004).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1961), урта мәктәптә физика укытучысы, 1971 елдан — Мөслим районы халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1974–1994 елларда — Казан педагогия институтында физика-математика факультеты деканы. 1990–1997 елларда — ТР мәгариф министры. 1997–2005 елларда — Татар гуманитар институты ректоры, 2006 елдан — Татар гуманитар-педагогика университетының физика факультеты деканы. Физика укыту методикасы һәм теориясе буенча хезмәтләр һәм урта мәктәп өчен дәреслекләр авторы.



В.Г.Гайфуллин

«Каюм Насыйри һәм хәзерге татар милли мәгарифе» мәкаләсендә В.Гайфуллин мәгърифәтче галим һәм әдипнең татар милли мәгарифен үстерүдәге ролен тасвирлый. «Ярты гасыр дәвамында тырыш һәм гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән галим, язучы, педагог Каюм Насыйри филология, педагогика, физика, математика, тарих, география, биология, астрономия һәм башка фәннәр турында кырыктан артык хезмәт иҗат итә. Бүгенге татар мәгърифәте өчен зур әһәмияткә ия булган титаник хезмәтләре татар халкының иҗтимагый уяну тарихында мактаулы урын ала», — дип яза. Ул галимнең төрле фәннәргә караган хезмәтләреннән математика буенча «Хисаплык», геометрия буенча «Гыйльме һәндәсә», география буенча «Истыйлахате җәгърәфия» (география терминнары), табигать белеме буенча «Буш вакыт», ботаника буенча «Гөлзар вә чәмәнзар», игенчелеккә караган «Гыйльме зирагать» (иген игү һәм бакча эше турында кулланма) исемле дәреслек һәм китапларының бүгенге фәндә дә олы мирас булуын раслый.

К.Насыйри хезмәтләрендә халык педагогикасының иң мөһим идеяләре киң урын ала. Бу биеклеккә ул күп еллар укытучы булып эшләп, шуннан алган бай тәҗрибәсе ярдәмендә ирешә. Мәгърифәтче галим мәгариф эшен кайнар яклый, татар халкының аң-белемен, мәдәниятен алга җибәрү омтылышы белән яши. Аның

мәгариф мәсьәләсендәге төп идеалы татарлар өчен гимназия һәм башка рус мәктәпләре тибындагы уку йортлары булдырудан гыйбарәт була. Шул максат белән ул 1872 елда башлангыч мәктәп оештыра һәм шатланып: «...хәзердә мәдрәсәнең сыйфаты гимназия классларыннан бер дә ким түгел»,– дип билгеләп уза. В.Гайфуллин әлеге язмасында К.Насыйриның әдәби-тарихи, иҗтимагый һәм педагогик эшчәнлеге татар, рус һәм башка халыклар җәмәгатьчелеге тарафыннан югары бәяләнүне икърар итә һәм, хәзерге татар мәгарифенең кайсы гына тармагын алсаң да, аның тамырлары олуг шәхес, мәгърифәтче галим хезмәтләренә барып тоташуын ассызыклый.

«ТАССР төзелүгә 100 ел» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри һәм хәзерге татар милли мәгарифе // Гыйльми язмалар (ТДГИ). Казан, 2003.10 чыг.; Каюм Насыйри һәм хәзерге татар милли мәгарифе // Зеленодольский регион: проблемы истории и культуры. Восток-Запад: диалог культур Евразии (серия «Проблемы истории и археологии»): сборник материалов конференции. Казань, 2003. Вып. 3; Язмыш борылышлары. Казан, 2007; Профориентационная работа на уроках физики. Казань, 1988; Активизация учения школьников. Казань, 1992; Национально-региональный компонент стандарта образования. Татарстанский вариант. Казань, 1999.

Ф.С.Гыйниятуллина.

«ГАКАЙД РИСАЛӘСЕ́» («Дин өйрәтмәләре»), чәчмә телдә язылган дини эчтәлекле китап. Каюм Насыйри аны 1859 елда ислам дине белән таныштыру максатыннан яза. Китап беренче тапкыр 1867 елда, «Гакаиде Исламия» («Ислам гакыйдәсе» — «Иман нигезләре») исеме белән дөнья күрә.

Эчтәлеге Аллаһның берлеген тануны, шәһадәт китерүне, аның күркәм сыйфатларын, пәйгамбәрләр тарихын бәян итүдән, шул исәптән Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның нәсел-нәсәбе белән таныштырудан гыйбарәт. Каюм Насыйри фикеренчә, динне өйрәнүдә бу пунктлар төп нигез булып тора.


عقايد رسالەسى

К.Насыйри. «Гакаид рисаләсе». Казан, 1896.

Икенче мәртәбә 1882 елда Казанда Г.М.Вечеслав басмаханәсендә Мөхәммәтнәҗип Галиәкбәр угылының матди ярдәме белән, өченче тапкыр 1896 елда Казан университеты басмаханәсендә, һәр икесендә хәзерге исемендә нәшер ителә.

Чыг.: Насыйри К. Гакаиде Исламия. Казан, 1867; шул ук. Гакаид рисаләсе. Казан, 1882; шул ук. Гакаид рисаләсе. Казан, 1896.

Әд.: Катанов Н. «Акаид рисалесы» (послание относительно вероучения). Казань, 1896. Типогр. ун-та. 24 стр. // Деятель. 1897. № 12.

Р.Ф.Исламов.

ГАЛИ́ (Галиев) Мөхәммәт Вәли улы (24.03.1893, Казан губернасының Лаеш өязе (хәзер Татарстанның Балык Бистәсе районы) Олы Елга авылы – 16.05.1952, Казан), язучы, журналист, әдәбият галиме.

«Касыймия» (Казан, 1910–1912), «Хөсәения» (Оренбург, 1912–1914) мәдрәсәләрендә укый. Казан университетын тәмамлый (1933). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1917–1919 елларда туган авылында укыта. 1919 елдан — Казанда: «Кызыл армия», «Эш», «Эшче», «Татарстан хәбәрләре» газеталарында, «Игенче» журналында эшли; Идел буе хәрби округының цензоры була. 1922–1924 елларда — «Безнең байрак», 1924–1929 елларда — «Крестьян газеты», 1929–1931 елларда «Кызыл Татарстан» газеталарында җаваплы сәркатип. 1933–1939 елларда Казан педагогия институтында, Казан берләштерелгән педагогия техникумында, КПСС өлкә комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм институтында укыта. Бөек Ватан сугышы елларында СССР Әдәби фондының Татарстан буенча вәкиле була, шулай ук Дәүләт музееның әдәбият бүлегендә эшли. 1946 елдан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында.

Хезмәтләрендә 19–20 йөз башы татар әдәбияты тарихы, Әбелмәних Каргалый, Габдерәхим Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави, Каюм Насыйри, Акмулла, Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Галиәсгар Камал, Сәгыйть Рәмиев, Шәриф Камал, Мәҗит Гафуриның тормыш юллары һәм иҗатлары яктыртыла. Беренче әсәрләре 1914 елдан башлап «Йолдыз» газетасында, «Аң» журналында басыла. «Сабан туенда» (1921), «Балалык көннәремдә» (1925), «Кала кешеләре булдык» (1928), «М.Гали әсәрләре» (1929–1931) китапларына кергән хикәя һәм очеркларында авылда революциягә кадәр һәм 1920–1930 еллардагы социаль үзгәрешләрне тасвирлый. «Теләнчеләр, яки бәхет эзләгәндә» (1936), «Имана» (1939), «Каюм Насыйри» (1945, Хөсәен Уразиков белән бергә) пьесалары, Каюм Насыйри турында язылып бетми калган роман авторы. «Газета укучылар өчен кесә сүзлеге»н (1928), «Русско-татарский словарь»ны (1941) төзүче.



М.В.Гали

«Каюм Насыйриның кулъязма мирасы» мәкаләсендә М.Гали әдип һәм галимнең кулъязмаларына (кара: *Каюм Насыйриның кулъязмалары*) игътибарын юнәлтә. К.Насыйри, аның фикеренчә, татар язучылары һәм галимнәре арасында иң күп кулъязма (үз кулы белән язган) әсәр калдырган язучы. Хәзерге көндә Казандагы төрле гыйльми оешмаларда Насыйриның 100 папка яки 100 төргәктән артык кулъязмасы саклана. Ләкин аларга барлык кулъязмалары да кереп бетмәгән. Беренчедән, Каюм кече яшьтән, мәдрәсәдә укыган вакыттан ук китап күчереп яза торган булган. Язуы матур һәм каләме йөгерек булганлыктан, ул үзе өчен генә түгел, билгеле хак бәрабәренә чит кешеләргә дә китап күчереп язган. Икенчедән, мәдрәсәдән чыгып, үзе әсәрләр язу эшенә керешкәннән соң, булган кулъязмаларны саклау, югалганнарын барлау эшенә дә нык әһәмият биргән.

М.Гали язганча, К.Насыйриның хәзергә кадәр тикшерелеп барланган кулъязмаларын ике зур төркемгә бүләргә мөмкин: 1) китап хәленә китерелгән кулъязмалар; 2) таркау кулъ-

язмалар. Китап хәлендәге кулъязмалар арасында 17 исемдәге басылган әсәрләренең, 4–5 еллык календарьларының, 15 исемдәге хәзергә кадәр басылганы булмаган оригиналь әсәрләренең кулъязмалары бар. Кайбер кулъязмалары икешәр данәдә сакланган, алар барысы да үз кулы белән язылган. К.Насыйриның «Кырык вәзир», «Ләһҗәи татари», «Лөгате рус», «Хисаплык», «Тарихы әнбия» һәм башка китапларының тулы кулъязмалары сакланган. «Кырык бакча», «Фәвакиһел-җөләса», «Гөлзар вә чәмәнзар» китапларының тулы нөсхәләре табылмый. К.Насыйриның таркау кулъязмалары китап кульязмаларына караганда да күбрәк һәм төрлерәк. Бу төркем кулъязмалар арасында күбрәк календарь материаллары, әдәби әсәрләр, сүзлекләр, терминнар, фольклор, тарихи материаллар, фәнни-статистик мәгълүматлар, истәлекләр, шулай ук авыл, кеше һәм үсемлек исемнәре бар. Аның уку-укыту эшләренә караган кулъязмалары арасында мәктәп программалары, укыту эшләре буенча законнар, циркулярлар, хисаплар, планнар, мәктәп әсбапларына инвентаризация документлары, укучылар исемлекләре, үзе тарафыннан төзелгән уку китапларын язу планнары, ул китаплар өчен татарча терминнар, иске татар дини мәктәп һәм мәдрәсәләрендәге уку-укыту тәртипләренә карата тәнкыйди язмалар бар.

Әдипнең төрле галимнәр, остазлары, әти-әнисе, туганнары белән язышкан, саны 500 дән арткан хатлары да әһәмиятле урын били (кара: *Каюм Насыйриның хатлары*). Чит кешеләр белән язышкан хатлары күбрәк басылган китаплары, календарьларына кагыла. Таркау кулъязмалары эчендә һәртөрле очраклы нәрсәләр: башлыча исенә төшкән сүзләре, башына килгән уйлары, күргән төшләре теркәлгән язулар да була. Кулъязмалар арасында шулай ук үз кулы белән бик матурлап ясалган төрле шәҗәрәләр, географик карталар, төрле урыннарның планнары очрый. К.Насыйриның бай архивына игътибар юнәлтеп, М.Гали янә аның күренекле галим, энциклопедист һәм киң диапазонлы язучы булуын ассызыклый.

Әсәр.: Тормыш юллары. Казан, 1940; Г.Камал. Казан, 1941; Сайланма хикәяләр. Казан, 1952; Шагыйрь баскан эзләрдән. Казан, 1957; Сайланма әсәрләр. Казан, 1964.

Хезм.: Каюм Насыйриның кулъязма мирасы // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Каюм Насыйриның басылмаган кулъязмасы // Совет әдәбияты. 1950. № 2.

Әд.: Әмирхан Р. Тыйнак талант // Татарстан. 1993. № 3; Гайнуллин М. Мөхәммәт Гали // Татар әдипләре (Иҗат портретлары). Казан, 1978; Рәмиев З. Талантлы язучы, күренекле галим // Казан утлары. 1993. № 3.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ГАЛИ́ЕВ МӘЧЕТЕ́ (башка исемнәре: Муса бай мәчете, Печән базары мәчете, 5 нче мәхәллә мәчете), классицизм стилендәге тарих-архитектура истәлеге. Казан шәһәре Вахитов



Галиев мәчете. Казан. 1798–1801 елларда төзелә. 20 йөз башы фотосурәте.

районының Иске Татар бистәсендә урнашкан.

1801 елда чыгышы белән Сәрдә авылыннан (Татарстанның хәзерге Саба районына керә) булган сәүдәгәр Муса Мәмәш (1812 елда вафат) акчасына төзелә. 1882 елда 2 нче гильдия сәүдәгәр Ибраһим Уразаев (1825



Галиев мәчетенең имам-хатибы, ахун Мөхәммәтйосыф Габделсаттар улы Сәгыйтов (1830–1909).

елда туган) мәчетнең көньягына архитектор П.И.Романов проекты буенча янкорма, 1897 елда 2 нче гильдия сәүдәгәрләр Мөхәммәтҗан Галиев (1832–1908) һәм Исмәгыйль Иманкулов (1834–1899) мәчет биләмәсенең көньяк-көнбатыш өлешендә ике катлы кирпеч флигель төзетәләр. Мәчетнең тарихы һәм эшчәнлеге ике руханилар нәселе белән тыгыз бәйләнгән.

Тәүге имамнарының берсе — Шырдан авылы кешесе Сәгыйть бине Әхмәт (1810 елдан; мәдрәсә оештыра). 1814 елда улы — күренекле шәригать белгече, Бохара әмире Мирхәйдәрнең якын киңәшчесе булган Габдессаттар Сәгыйтов икенче мулла итеп раслана. Сәгыйть әш-Шырданиның икенче улы шул ук елларда әтисенә мәдрәсә белән җитәкчелек итүдә булыша башлый. 1831 елдан мәхәлләне — Сәгыйть хәзрәтнең кече улы Әхмәт Сәгыйтов (1793–1867), 1867 елдан — Мөхәммәтйосыф Сәгыйтов (1830–1909), 1909 елдан — Галимҗан Барудиның энесе Габдрахман Галиев, 1913–1917 елларда күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, җәдитчелек хәрәкәтен оештыручыларның берсе, 1882 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ачкан Галимҗан Баруди җитәкли. 20 йөз башында мәчетнең мәхәлләсе Тихвин, *Печән базары*, Олы Мещан, Евангелистлар урамнарын били, анда 690 ир-ат яшәгән 75 йорт исәпләнә.

Мәчет күп еллар дәвамында татар халкының рухи-агарту элитасын тәрбияләгән, анда гыйбадәт кылучылар арасында мәгърифәтчеләр Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Галимҗан Баруди була.

Әд.: Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (№ 126). Казан, 1995; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры (№ 1431). Казань, 1993.

И.Х.Хәлиуллин.

ГАЛИ́ЕВА Ләлә Исмәгыйль кызы (31.01.1928, Татарстанның Чаллы кантоны Чаллы авылы – 06.01.2010, Казан), педагог, ТАССРның атказанган мәктәп укытучысы (1972), Халык мәгарифе отличнигы. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1995).

Чаллыдагы Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәпне тәмамлаганнан соң (1945), Казан педагогия институтының тарих-филология факультетында белем ала. 1947–2002 елларда

Казан шәһәренең 47 нче мәктәбендә (35 нче татар мәктәбе, 1 нче гимназия) укыта.



Л.И.Ғалиева

Л.Галиеваның фәнни-педагогик хезмәтләре укыту-тәрбия мәсьәләләренә карый. Дәреслекләр, методик кулланмалар авторы.

Хезм.: Диктантлар җыентыгы: 1–4 нче классларда эшләүче укытучылар өчен ярдәмлек. Казан, 1990 (автордаш); Әдәплелек дәресләре. 1–3 нче сыйныфлар: Укытучылар өчен кулланма. Казан, 1995 (автордаш); Көч һәм рух тамырлары. Әдәплелек дәресләре: 1–3 нче сыйныфлар өчен хрестоматия. Казан, 2000 (автордаш); Методические указания, упражнения и задания к «Дидактическому раздаточному материалу». Казань, 1967.

Әд.: Вәлиев М. Укытучы — фәнни тикшерүче // Мәгариф. 2004. № 1; Мифтахова Ф., Исхакова А. Канатлар талмый // Мәгърифәт. 1996. 5 апрель; Якын киңәшче // Совет мәктәбе. 1978. № 1.

Ф.С.Ғыйниятуллина.

ГАНИ́ЕВА Резеда Кадыйр кызы (13.11.1932, Норлат (хәзер Яшел Үзән) районы Кече Шырдан авылы – 21.03.2020, Казан), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1992), профессор (1993). ТРның атказанган фән эшлеклесе (1994).

Казан университетын (1958), Мәскәү университеты аспирантурасын (1962) тәмамлый. 1951–1958 елларда Норлат, Биектау районнары һәм Казан мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1962 елдан Казан университетында: 60 ел чамасы студентларга гарәп, фарсы, төрки һәм татар әдәбиятлары тарихы укыта.

Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына һәм теориясенә, Шәрекъ һәм төрки-татар әдәбиятларындагы Яңарыш хәрәкәтенә, иҗат ысуллары мәсьәләләренә, татар әдәбиятының Көнбатыш Европа, рус, украин, гарәп, фарсы-тажик, төрки әдәбиятлары белән багланышларына, Кол Гали, Мәүлә Колый, Габдерәхим Утыз Имәни, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думави, Шәехзадә Бабич, Рәдиф Гаташ иҗатларына карый.

Каюм Насыйри турында мәкаләләр авторы. Р.Ганиеваның «Кадерле Каюм бабабыз» һәм «Каюм Насыйри — яңа заман татар Ренессанс хәрәкәтен башлап җибәрүче» язмаларында К.Насыйри эшчәнлегенә аеруча зур игътибар бирелә. Галимә фикеренчә, татар әдәбиятында Яңарыш хәрәкәте өч баскыч үтә. Аның беренче баскычы Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорына — дәүләтләребез булган вакытларга туры килә. Рус дәүләтенә кушылгач, халкыбыз торгынлык халәтенә дучар була. Бары тик 19 йөзнең 2 нче яртысыннан, К.Насыйриның эшчәнлеге белән бәйле рәвештә, татар халкының Яңарышка — европалашуга омтылышы башлана. 20 йөзнең 1 нче чирегендә исә татар мәдәнияте, әдәбияты, җәдитчелек идеологиясе казанышларына таянып, моңарчы күрелмәгән Яңарыш биеклекләренә күтәрелә, поэзия, проза һәм драматургия яңа үсеш чорына аяк баса. 20 йөз ахырында, коммунистик идеология тарих сәхнәсеннән төшкәч, алгарыш һәм дә чигенешләр белән татар халкының өченче Яңарышы башланып китә. Ул әле бүген дә дәвам итә. Моның шулай икәнлеген Р.Ганиева К.Насыйри иҗатын өйрәнүдә эзләнүләр алып баручы буларак раслый. Аның мәгърифәтче

турында әйткән сүзләре игътибарга лаек: «...Каюм Насыйриның иҗатына мөрәҗәгать итүемнең бер сәбәбе — ул татар әдәбиятындагы икенче Яңарышны башлаучы булып тора. Зур авырлыклар аша үтә-үтә килеп, 19 йөз уртасыннан Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗаниләр кебек олы мәгърифәтчеләребез мәйданга чыга. Алар — татар халкының дини, дөньяви яңаруын тәэмин итүчеләр. Шуңа күрә атаклы мәгърифәтче, этнограф Каюм Насыйри татар халкының икенче Яңарышын башлап җибәрүче һәм шуның нигезен салучы», — дип нәтиҗә ясый һәм К.Насыйриның замандашлары арасында беренчеләрдән булып әдәбият һәм фән телен халыкның сөйләм теленә якынайту мәсьәләсен күтәреп чыккан әдип, тарихчы, танылган тел белгече булуын искәртә, татар теленең гыйльми нигезләрен булдыруда, халык авыз иҗаты әсәрләрен бастыруда, алар белән башка халыкларны таныштыруда, әдәбиятны яңа сыйфатлар белән баетуда үзеннән зур өлеш кертеп, бай әдәби-мәдәни мирас калдырган шәхес, татар мәдәниятендә инкыйлаб ясаган бөек галим булуын яктырта.



Р.К.Ганиева

ТРның «Фидакарь хезмәт өчен», Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Думавиның иҗат сәхифәләре. Казан, 2003; Шагыйрьнең рухи дөньясы. Казан, 2003; Каюм Насыйри — яңа заман татар Ренессанс хәрәкәтен башлап җибәрүче // Зеленодольский регион: проблемы истории и культуры. Восток-Запад: диалог культур Евразии (Серия «Проблемы истории и археологии»): сб. матер. конф. Казань, 2003. Вып. 3; Сатира в творчестве Тукая. Казань, 1964; Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань, 1988; Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань, 2002.

Әд.: Бакиров М.Х. Чын галим һәм педагог // Фәнни Татарстан. 2002. № 3/4; Миңнегулов Х. «Каюм баба»ның дәвамчысы // Гасырлар өнен тыңлап. Казан, 2003; Саяпова А. Говорю о своем учителе // Идель. 2002. № 10.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ГАРИ́Ф Нурулла Гыймадетдин улы (01.09.1960, Татарстанның Балык Бистәсе районы Яңа Сала авылы), педагог, тарихчы, тарих фәннәре кандидаты (2006), язучы. ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2000), ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге әдәби бүләге иясе (2024), ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2015).

Казан радиотехника мәктәбен (1982), Казан университетын (1988) тәмамлый. Биектау, Балык Бистәсе районнары мәктәпләрендә физика, математика, информатика укыта. Мәктәптә эшләү дәверендә татарларның борынгы тарихы һәм археологиясе белән кызыксына башлый. Болгар (Биләр, Җүкәтау, Чаллы, Өтернәс, Иске Казан, Кирмән), Алтын Урда (Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдид, Хаҗитархан, Үкәк һ.б.) шәһәрлекләренә оештырылган археологик экспедицияләрдә катнаша. Туган төбәгендәге авыллардан борынгы чорларга караган күп кенә кулъязмалар җыеп, ТР Милли китапханәсенә һәм Кол Шәриф мәчете китапханәсенә тапшыра.



Н.Г.Гариф



Р.Ә.Гатиятуллина

Әдәби эшчәнлеге дә, нигездә, татар тарихы белән бәйле. Хезмәтләрендә тарихка нисбәтле фәнни һәм фәлсәфи язмалар, гыйбрәтле хикәяләр өстенлек итә. Аның журнал битләрендә басылган «Борынгы Чаллы» («Казан утлары», 1996, №3), «Тамгада — тарих эзләре» («Мирас», 2000, №1), «Үткәннәргә сәяхәт» («Казан утлары», 2003, №4) һәм башка фәнни-публицистик хезмәтләре татар халкының 1552–1556 еллардагы азатлык сугышларына карый. «Мәмеш Бирде» тарихи хикәясендә («Казан утлары», 1999, №8) татар тарихындагы катлаулы чорлар яктыртыла. Гарифның тырышлыгы белән Балык Бистәсе районында урнашкан борынгы Чаллы шәһәрлеге дәүләт тарафыннан сакланылучы федераль дәрәҗәдәге тарихи тыюлык булып билгеләнә. Үзенең туган авылында, бабалары нигезендә музей оештыра.

Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Без кемнәрнең оныклары әле?!.. Казан, 2003; Изге учак монда сүнмәгән. Казан, 2003; Мин сезнең арада яшәдем: эссе, парчалар, баллада, юлъязма. Казан, 2003; Борынгы Чаллы: саклап кала алырбызмы? = Древние Чаллы: сумеем ли сохранить? Казан, 2004; Борынгы Чаллы төбәге: документлар телендә сөйләшәбез. Казан, 2005; Казан ханлыгы (оешу тарихы, идарә системасы, административ бүленеше һәм феодал вассаллык мөнәсәбәтләре. Чаллы олысы мисалында). Казан, 2006; Нәселеңә корт керсә. Гыйбрәтле хикәятләр. Казан, 2008.

Ф.Г.Камальтдинова.

ГАТИЯТУ́ЛЛИНА Рәзинә Әнвәр кызы (16.10. 1978, ТАССРның Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылы), педагог, филолог, музей эшлеклесе.

Казан университетын тәмамлый (2001), шул ук елдан — Каюм Насыйри исемендәге *Архитектура-этнография комплексы* мөдире.

Музей җитәкчесе буларак, К.Насыйриның төрле өлкәләргә караган хезмәтләрен, мәсәлән, халык авыз иҗатын тикшерүгә нисбәтле, тәрбия-әхлак турындагы хезмәтләрен өйрәнә һәм үз эшендә алардан оста файдалана. К.Насыйриның 1999 елда нәшер ителгән «Шифалы үләннәр» китабына кыскача анализ ясый. Аның җитәкчелегендә музей, шул китапка нигезләнеп, яздан көзгә кадәр үләннәр җыя, алардан хуш исле чәйләр әзерли һәм комплексна килгән кунакларга тәкъдим итә; Татарстанда һәм чит төбәкләрдә үткән төрле бәйрәм чараларында катнашып, 19 йөз ахыры – 20 йөз башы урта хәлле крестьян тормышы белән таныштыра; район һәм республика матбугатында К.Насыйригa, тел-әдәбият мәсьәләләренә караган, музей-комплекс катнашында уза торган мәдәни чаралар турындагы язмалары белән чыгыш ясый.

ТР Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.


Ф.Г.Камальтдинова.

ГЕОМЕ́ТРИЯ (грек теленнән ge — Җир һәм metron — үлчәү), кара: *«Гыйльме һәндәсә»*.

ГЕОГРА́ФИЯ (грек теленнән ge — Җир һәм graphein — язу), Җирдәге тереклекнең табигый һәм иҗтимагый шартларын өйрәнә торган үзара бәйләнештәге фәннәр комплексы. Өйрәнү объектына карап, физик географиягә һәм иҗтимагый-икътисади географиягә бүленә. Физик географиягә — геоморфология, климатология, гидрология, туфрак географиясе, биогеография, ландшафт белеме; иҗтимагый-икътисади географиягә халык, сәнәгать, авыл хуҗалыгы географиясе бүлекләре керә. Һәр фәннең гомуми һәм региональ бүлекләре бар. Шулай ук барлык география фәннәренә хезмәт күрсәтә торган картографияне дә географиягә кертәләр.

Татар халкының көндәлек тормышына географик гыйлемне системалы өйрәнү традицияләре Идел буе Болгар дәүләте чорыннан керә башлый, һәм ул Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверләрендә яңа үсеш ала. 19 йөздә татарлар арасында, шул исәптән мәктәп-мәдрәсәләр һәм рус-татар мәктәпләре аша милли телдә география буенча белемнәр таралу Каюм Насыйри исеме белән бәйле. Ул «Осуле җәгърәфияи кәбир (Азия кыйтгасы)» (1894), «Осуле җәгърәфияи кәбир (Африка кыйтгасы)» (1898), «Осуле җәгърәфияи кәбир (Гарәбстан, Шам, Гыйрак мәмләкәтләре хакында)» (1899), «*Истыйлахате җәгърәфия*» (1890), «Оусаф җәзирәт әл-гарәб» («Гарәбстан географиясе», аның кулъязмасы Казан университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге* фондында саклана) дәреслекләрен яза. Шулай ук Россия географиясе буенча дәреслек эшли һәм мәктәп атласын төзи, алар басылмыйча кала.

Мәгърифәтче шулай ук үзенең фәнни тикшеренүләрендә, педагогик эшчәнлегендә махсус җайланмалар һәм күрсәтмә материаллардан (мәсәлән, замандашы Әхмәт Хөсәенов К.Насыйри яшәгән фатир диварларында төрле гео-




Каюм Насыйри тарафыннан төзелеп, башлыча татарлар тупланып яшәгән урыннар, Кыйблага юнәлеш күрсәтелгән карта.

график карталар эленеп торуы, өстәлендә глобуслар, картиналар, силомер һәм башка әсбапларның чәчелеп ятуы хакында искә ала; хатирәләрдә (кара: *Истәлекләр*) галимнең үзенең дә карталар сызуы хакында мәгълүматлар очрый, карталарның кайберләре Казандагы *Каюм Насыйри музеенда* урын алган), шул исәптән үз куллары белән ясаган күк җисемнәре дөньясы глобусыннан (*Татарстан Республикасы Милли музеенда* саклана) файдалана. Аның хезмәтләре һәм кулланмалары киң даирәне чит илләр белән таныштыруда, белемнәрне баетуда мөһим роль уйныйлар, яңа дәреслекләр барлыкка килүгә этәргеч бирәләр. 1897–1902 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә физика һәм география укыткан Х.Фәйзи-Чистапулиның 1915 елда «География дәреслеге» дөнья күрә. Шулай ук кара: «*Осуле җәгърәфия*».



Каюм Насыйриның үз куллары белән ясаган күк җисемнәре дөньясы глобусы.



Каюм Насыйри тарафыннан 1871 елда төзелеп, аның календаренда басылган Казан губернасы картасы.

Әд.: Хәйруллина Н. К.Насыйри — география дәреслекләре авторы // Совет мәктәбе. 1982. № 11.

И.Х.Хәлиуллин.

ГОБӘЙДУ́ЛЛИН Газиз (Габделгазиз) Салих улы (Г.Газиз) (15.06.1887, Казан – 13.10.1937, Баку, Әзәрбайҗан ССР), тарихчы, тарих фәннәре докторы (1927), профессор (1927), җәмәгать эшлеклесе, публицист. Казандагы Шәрекъ академиясен нигезләүчеләрнең берсе (1922).

«Халидия» мәдрәсәсен (1904), Казан университетының тарих-филология факультетын (1916) тәмамлый. Шәкертләрнең «әл-Ислах» хәрәкәтендә катнаша. «Шимбә» театр түгәрәге әгъзасы. Университетта укыганда, татар студентлары түгәрәген (Нәҗип Хәлфин, Галимҗан һәм Борһан Шәрәфләр, Гафур Коләхмәтов, Фуад Туктаров, Мәрьям Гобәйдуллина һ.б.) оештыручыларның берсе була. 1914 елдан — педагогик эштә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих фәне укыта. 1916–1917 елларда — «Вазифа» мөселман мәктәбе (Троицк шәһәре) мөдире. 1917–1918 елларда татар милли азатлык хәрәкәтендә актив катнаша; Милли Шура башкарма комитеты әгъзасы, Милләт Мәҗлесе депутаты, Идел-Урал штатын гамәлгә кертү һәйәте әгъзасы. 1917 елның җәендә Бөтенроссия мөселман укытучылары съездында катнаша, башкарма комитет әгъзасы булып сайлана.

1921 елда Н.Ф.Катанов һәм Н.А.Фирсов җитәкчелегендә Казан университеты каршында аспирантура тәмамлаганнан соң, фәнни һәм педагогик эштә; 1922–1925 елларда — Шәрекъ педагогия институты укытучысы; бер үк вакытта — ТАССР Мәгариф Халык Комиссариаты *Гыйльми үзәге*, Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте әгъзасы, ТАССР Үзәк музее хезмәткәре. 1925 елда гаиләсе белән Бакуга күчеп китә; Әзәрбайҗан университетының Шәрекъ факультетын һәм Югары педагогия институтын оештыручыларның берсе. 1925–1933, 1935–1937 елларда — Әзәрбайҗан университетында Шәрекъ факультеты деканы, төрки-татар халыклары тарихы кафедрасы мөдире, 1935 елдан Якын Көнчыгыш тарихы кафедрасы мөдире. Бер үк вакытта Үзбәкстан ССР Гыйльми үзәге белән хезмәттәшлек итә; 1925 елның августында Гыйльми үзәк каршындагы Үзбәкләр тарихын һәм телен өйрәнү комитеты эшендә катнаша, Үзбәкстан ССР Мәгариф халык комиссариаты Гыйльми үзәге каршындагы Үзәк мәгариф бюросы рәисе була. 1928 елда Сәмәрканд югары педагогия институтының мөселман Шәрегы кафедрасы профессоры итеп сайлана. 1 нче Бөтенсоюз тюркология съездында (1926, Баку) катнаша. 1930–1931 елларда Мәскәү университетында лекцияләр укый. 1931–1933 елларда — Советларның гомумәзәрбайҗан съезды делегаты, Баку шәһәренең Ворошилов район советы депутаты, Әзәрбайҗан Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы фәнни-тикшеренү институтының тарих секциясе җитәкчесе. 1934 елда ТАССР Мәгариф халык комиссариаты чакыруы буенча Казанга кайта, 1934–1935 елларда Марксизм-ленинизм фәнни-тикшеренү институтында, Казан университетында эшли. СССР Үзәк Башкарма Комитеты Коммунистик академиясе каршындагы Тарих-



Г.С.Гобәйдуллин

чы-марксистлар җәмгыяте әгъзасы (1928).

Хезмәтләре татар халкы тарихына, татар әдәбиятына, Идел буенда һәм Әзәрбайҗанда барган крестьян сугышлары тарихына карый. Беренче публицистик язмалары «Корылтай», «Алтай» газеталарында, «Укытучы», «Аң» журналларында басыла. Сатирик һәм юмористик хикәяләр остасы. «Җомга көн», «Исерек» (икесе дә 1913 елда), «Чалбар» (1915) сатирик новеллалары, Гаяз Исхакый, Сәгыйть Рәмиев ижатлары, 20 йөз башы татар әдәбиятында романтизм (1911–1913 елларда басыла) турындагы әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы. Шул ук дәвердә тарихчы галимнең тарих буенча беренче уку әсбаплары — «Борынгы заман тарихы», «Диннәр тарихы», «Россия тарихы» дөнья күрә. Татарстан тарихы буенча документлар җыентыгы әзерләүдә, Каюм Насыйрины искә алу чаралары, төрле юбилейларын үткәрүдә катнаша.

ТАССР Мәгариф халык комиссариаты Гыйльми үзәге тарафыннан 1922 елның 2 сентябрендә Каюм Насыйриның вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте белән ядкәр көне уздырырга карар кылына. Моны башкарып чыгу өчен өч кешелек комиссия төзелә. Аның рәисе итеп Галимҗан *Ибраһимов*, әгъзалар сыйфатында Сәлах Атнагулов һәм Газиз Гобәйдуллин билгеләнә. Комиссия К.Насыйри турында 10–15 табаклык мәҗмуга чыгару чарасына керешә, мәгърифәтче турында азмы-күпме мәгълүматы булган кешеләргә комиссия белән мөнәсәбәткә кереп, ядкәр мәҗмугасының тулы чыгуына кулларындагы материаллар, язулар, хатирәләр, китаплар, рәсемнәр белән ярдәм итү турында мөрәҗәгать ителә. Г.Гобәйдуллин үзе дә К.Насыйри хезмәтләрен актив өйрәнә, аның турында мәгълүматлар җыя (туган авылы Югары Шырданга да барып кайта), 1922–1925 елларда мәгърифәтче галимгә багышлап чыгарылган җыентыкларын төзүче һәм авторларының берсе була (моңарчы нәшер ителмәгән әсәрләрен эзләп табып, редакцияли һәм аларны бастырып чыгара). К.Насыйриның археология һәм этнография буенча язмалары һәм башка шундый әһәмияткә ия әсәрләре шул рәвешчә дөнья күрә. 1923 елда «Татар календаре» дип аталган хезмәттә ул Ибраһим Кулиев белән берлектә Мулланур Вахитов, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай һ.б. турында мәкаләләр бастыра.

Репрессияләр чоры корбаны, үлгәннән соң аклана.

Хезм.: Каюм Насыйриның гыйльми-тәгълими хезмәтләре // Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. 1922; Насыйри чын гыйлем-фән бабында // шунда ук чыга; Татар тарихы. Казан, 1922; Борынгы болгарлар. Казан, 1924; Пугачёв явы. Казан, 1924; Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда. Казан, 1924; Крестьян сугышлары тарихы. Казан, 1933; Пугачёвщина и татары. Баку, 1927; Из прошлого татар. Лондон, 1990; История татар. М., 1994.

Әд.: Гобәйдуллин С.Г. Безнең әтиебез // Татарстан. 1993. № 10; Алишев С.Х. Газиз Губайдуллин как историк // Исследования по историографии Татарии. Казань, 1978; Ашнин Ф.Д., Алпатов В.М. Гибель профессора Губайдуллина // ALTAICAII: Сб. статей и материалов. М., 1998; Насретдинова Д. Газиз Губайдуллин. Автобиография // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1997. № 1/2; Шигабдинов Р. Узбекский период научной деятельности профессора Газиза Губайдуллина // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1/2.

Д.М.Галиуллина, Ф.С.Гыйниятуллина.

ГОБӘЙДУ́ЛЛИНА Асия Наил кызы (07.02.1958, Норлат (хәзер Яшел Үзән) районы Кече Шырдан авылы), төзүче инженер, җәмәгать эшлеклесе. ТРның атказанган төзүчесе (2007). Әнисе ягыннан Каюм Насыйриның туганы.



А.Н.Гобәйдуллина

Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлаганнан соң, 1980–2002 елларда — Главтатстройның 2 нче төзелеш трестында инженер, проектлау буенча баш белгеч, 2002 елдан «Акведук» ҖЧҖ проектлау оешмасында проект баш инженеры, техник директор булып эшли, 2006 елдан — директор. А.Гобәйдуллина җитәкчелегендә торак йортлар («Замандаш», «Симфония» микрорайоннары һ.б.), медицина максатындагы биналар («Ава-Казан» медицина үзәге, Казан университетының медицина кластеры объектлары), кунакханәләр, уку корпуслары, административ биналар, дини корылмалар, сәүдә комплекслары һ.б. проектлана.

Иҗтимагый-хәйрия эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Каюм Насыйриның туган авылын торгызу, туып-үскән нигезен, мирасын саклауга күп көч куйган шәхес. 2015 елдан «Бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган җире — тарихи авыл Кече Шырданны торгызу» фонды» коммерциячел булмаган оешмасын төзүдә башлап йөрүче һәм аның башкарма директоры. Кече Шырдан авылында мәгърифәтченең рухын, төсен саклаган ике тарихи һәйкәл — *Каюм коесы* (Насыйровлар гаиләсе коесы) һәм К.Насыйри акчасына 1902 елда салынган, хәйрияче тырышлыгы белән яңартылган мәчет бинасы бар. Авылда шулай ук Каюм Насыйри исемендәге Гыйльми үзәк, китапханә-музей эшли.

Хезм.: Каюм Насыйри авылының киләчәге булырга тиеш // Шәһри Казан. 2019. 22 февраль.

Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Камальтдинова.

ГОРО́ХОВ Василий Михайлович (01.03.1891, Вятка губернасының Алабуга өязе Олы Елау авылы – 07.10.1960, Казан), педагог, тарихчы, педагогика фәннәре докторы (1950), профессор (1950).

Казан үзәк керәшен татар мәктәбен (1907), Казан укытучылар семинариясен (1911), Иркутск университетын (1922) тәмамлый. 1922 елдан — Казанда: Керәшен педагогия техникумында укытучы. 1930 елдан — Казан педагогия институтында: 1934 елдан — педагогия факультеты деканы, бер үк вакытта, 1952 елдан, педагогия һәм психология кафедрасы мөдире.

Хезмәтләре халык мәгарифе тарихына, балалар йортларында тәрбия мәсьәләләренә карый. 1945 елда «Кызыл Татарстан» газетасында басылган күләмле «Бөек татар галиме Каюм Насыйри (Тууына 120 ел тулуга карата)» мәкаләсендә ул чорда галимнең киң совет җәмәгатьчелегенә аз мәгълүм булуына борчылуын белдерә, аның этрафлы эшчәнлеген бәян итә, әлеге мәсьәләнең тирән игътибар белән өйрәнелергә тиешлеген ассызыклый. Каюм Насыйрины татар әдәбиятына нигез салучы, татар теле нигезләрен фәнни яктан эшләүдә үз өстенә күп хезмәт йөкләп алган беренче татар галиме, татарларның беренче галим-энциклопедисты, татар балаларына рус телен өйрәтү эшендә пионер дип атый, аның татар халкы арасында фәнни белемнәр җәелдерүдә гаять зур роль уйнавына, төрле фәннәр-

дән кулланмалар һәм дәреслекләр, 24 ел буе календарьлар төзүенә һәм аларны үз исәбеннән бастыруына, татарларны — рус, русларны татар мәдәнияте белән таныштыруына, рус галимнәренең Каюм Насыйриның фәнни эшчәнлеген югары бәяләвенә игътибар юнәлтә, тәрҗемәче буларак Каюм Насыйри «татарларда үз телләрендә матур әдәбият укуга ләззәт уятты», дип яза.

К.Насыйриның шәхесе иҗтимагый яссылыкта һәм педагогик җәһәттә Гороховның 1948 елда рус телендә нәшер ителгән «Каюм Насыйриның иҗтимагый һәм педагогик карашлары» мәкаләсендә яктыртыла. Анда галимнең иҗтимагый һәм педагогик карашлары формалашуда йорт-гаиләдә, җәмгыятьтә хөкем сөргән чынбарлыкның, алдынгы фикерле шәхесләр белән аралашуның йогынтысы булуы, аның татар мәдрәсә-мәктәпләрендә тамыр җәйгән мөселман схоластикасына, берьяклы тәрбия һәм белем бирү тәртипләренә, милли һәм дини чикләнүгә каршы чыгуы, кеше акылының көченә һәм җиңеп чыгачагына ышануы, татарларны агартуда мөһим роль уйнавы, 19 йөзнең 2 нче яртысында бер генә татар галименең яки педагогының да татарлар өчен туган телнең роле һәм әһәмияте хакындагы мәсьәләне көн тәртибенә К.Насыйри дәрәҗәсендә үк кискен итеп куймавы икърар ителә.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Хезм.: Бөек татар галиме Каюм Насыйри (Тууына 120 ел тулуга карата) // Кызыл Татарстан. 1945. 7 гыйнвар; Мәктәптә тәрбия эшләре. Казан, 1955; Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. Казань, 1941; Выдающийся татарский учёный, просветитель и педагог Каюм Насыров // Красная Татария. 1945. 7 января; Кураловский детский дом. Казань, 1946; Школьное образование среди татар в 19 – начале 20 вв.: В 2 т. Казань, 1947; Общественные и педагогические взгляды Каюма Насыри // Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвящённых 120-летию со дня рождения). Казань, 1948.

Әд.: Ханбиков Я.И. Из истории педагогической мысли татарского народа. Казань, 1967.


И.Х.Хәлиуллин.

ГО́ТВАЛЬД Иосиф Фёдорович (13.10.1813, Германиянең Ратибор шәһәре – 07.08.1897, Казан), шәркыятьче галим, философия докторы (1836), Петербург Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1870).

Бреслав университетын тәмамлый. 1838 елдан — Россиядә. 1841–1846 елларда — Санкт-Петербургтагы Император җәмәгать китапханәсенең Көнчыгыш бүлегендә китапханәче. 1846 елда мөселман кануннары җыентыгын төзү комитеты эшчәнлегендә катнаша. 1849 елдан — Казан университетында: гарәп һәм фарсы телләре профессоры, 1850 елдан — китапханәче, бер үк вакытта, 1855–1875 елларда, шәркый әсәрләрне тикшерү буенча Казан бүлеге цензоры, 1857–1884 елларда — Казан университеты басмаханәсе башлыгы, 1859–1862 елларда — инглиз теле укытучысы.

Хезмәтләре Шәрекъ филологиясе һәм тарихына карый. Башка шәркыятьче галимнәр (Н.Ф.*Катанов*, В.В.*Радлов*, Г.С.*Саблуков* һ.б.) кебек үк Каюм Насыйри белән тыгыз аралаша, аның фәнни-мәгърифәтчелек эшчәнлегенә, галим булып җитешүенә йогынты ясый. Заманында 2500 дән артык исемдәге китап (шулардан 870 берәмлек — Көнбатыш Европа телләрендә, басма хәлдә; 268 берәмлек — кулъязма хәлендә) исәпләнгән шәхси китапханәсендә татар

тарихы һәм филологиясенә караган басмалар да зур урын алып торган, шул исәптән Каюм Насыйриның 30 хезмәте: 1879–1883, 1885, 1891, 1892, 1894 елларга нисбәтле чыгарылган календарьлары, «Тулы русча-татарча сүзлек» (1892), «Зөбдәт мин тәварихы әр-Русь» («Россиянең кыскача тарихы», 1890) басмалары, Казан губернасының татар телендәге картасы (1874), «Кабуснамә»се (1882) һ.б. сакланган. Готвальд шәхси китапханәсен һәм үз әсәрләре тупланмасын Казан университетына васыять итеп калдыра. Җыелманың бер өлеше, шул исәптән Каюм Насыйри кулъязмалары һәм китаплары бүгенге көндә университетның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә* саклана.




И.Ф.Готвадьд

Хезм.: Описание арабских рукописей, принадлежащих библиотеке Императорского Казанского университета. Казань, 1855; Опыт арабско-русского словаря на Коран, семь моаллакат и стихотворения Имрулькейса. Казань, 1863; Разбор сочинения А.Я.Гаркави «Сказания мусульманских писателей о славянах и русских». СПб., 1872; Хикам (изречения) Ходжи Ахмеда Ясави на джагатайском языке. Казань, 1878.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). Казань, 1904. Ч. 1; Катанов Н.Ф. Императорского Казанского университета почётный член, профессор и библиотекарь Иосиф Фёдорович Готвальд. Казань, 1900.

И.Х.Хәлиуллин.

«ГӨЛЗА́Р ВӘ ЧӘМӘНЗА́Р», үләннәрнең һәм чәчәкләрнең латин, татар, рус, гарәп телләрендәге атамалары һәм аларны дару үләннәре буларак файдалану турындагы китап. Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1894 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә. Әлеге хезмәтен язганда, ул В.Горецкий һәм Вильк тарафыннан нәшер ителгән, ике кисәктән торган «Рус халкының дәва үләнләре һәм чәчәкләре» («Русский народный лечебный травник и цветник», Мәскәү, 1885) китабыннан файдалана.


(گلزار وچمنزار)

بعنی

اولنلك وچيكلك

К.Насыйри. «Гөлзар вә чәмәнзар». Казан, 1903.

Китап әүвәл «*Хәвасе нәбатат*» исеме белән, басылган урыны һәм авторы күрсәтелмичә, 1886 елда нәшер ителә. Ун ел дәвамында К.Насыйри текстка төзәтмәләр кертә, күп урыннарын кыскарта, китапның күләме 34 биткә кечерәя. Анда төрле үләннәрдән, чәчәкләрдән, үсемлек тамырларыннан, орлыклардан, җимешләрдән, яфраклардан, кабык-кайрылардан 33 төрле авыруга дәва бирүче

76 төрле дару ясау ысулы өйрәтелә, авыру төрләре исемлеге китерелә. Ахырда кушымта рәвешендә 313 үлән һәм чәчәкнең татарча-гарәпчә-латинча-русча сүзлеге бирелә. Ул, титул битендә искәртелгәнчә, 1888 елгы календарьда басыла.

К.Насыйри үз китабы турында мондый аңлатма яза: «Мәгълүм ула ки, заманымызга кадәр үз телемездә тасниф кылынмыш [язылган] вә таләба лил-шифа истигъмаль кылып [тиешле шифасын файдаланып], мәнфәгать хасыйл итмәгә лаек бер тыйб китабы мәүҗүд [бар] булмаганлыктан, күп заманнар тыйб фәнендә бер китап тасниф вә тәрҗемә итеп табыг кылдырсам [бастырсам] икән дип күңелемдә бар иде вә галә һәза дәхи бәгъзе әхиббабымның тәшвикы вә илтимасы икътизасынча [дусларымның өндәүләре һәм үтенечләре теләкләренчә] бу әмер мөһим хосусында тәсвифяр имәс [кичектерү ярамас] дип, ошбу «Хәвасе нәбатат» тәсмия кылынмыш [исем аталмыш] рисаләмнең тасниф вә тәрҗемәсенә шөругъ кылдым [башладым] әл-фәкыйрь ән-Насыйри мең өч йөз бишенче — мең өч йөз унынчы еллар әснасында (арасында)».

Нашире китап белән сәүдә итүче Исмәгыйль Шәмсетдинов булган икенче басмасы 1903 елда, шулай ук Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә, ләкин анда сүзлек юк. Шуңа күрә үсемлекләрнең татарча-русча-латинча атамалары мәкалә башында бирелә. Кыскартылган тексты К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1953, 1956), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томына да (1974) да урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Гөлзар вә чәмәнзар. Казан, 1894; шул ук. Шифалы үләннәр. Хәвасе нәбатат / текстны басмага әзерләүче З.Шәйхелисламов. Казан, 1999.

Әд.: Шәйхелисламов З. Энциклопедист-галимнең хезмәте // Насыйри К. Шифалы үләннәр. Хәвасе нәбатат. Казан, 1999.

Р.Ф.Исламов.

ГӨЛНА́Р ХАНЫ́М (псевдоним, чын исем-фамилиясе Лебедева (Барщёва) Ольга Сергеевна) (1854, Казан – ?), шәркыятьче галимә, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче, публицист. Казан шәһәре башлыгы (1883–1886, 1889–1903), юрист А.А.Лебедевның (1843–1910) хатыны.

Казан университетында укый. Каюм Насыйри җитәкчелегендә татар, фарсы, гарәп һәм төрек телләрен өйрәнә. Император шәркыять җәмгыятен төзүдә башлап йөри (1900), аның мактаулы рәисе була, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы.

Халыкара шәркыятьчеләр конгрессларында катнаша. 12 нче конгресста (Рим, 1899) Казан татарлары тарихы турында ике доклад белән чыгыш ясый, алар соңыннан аерым китап булып басылып чыга. Беренче докладта Казан ханлыгының сәяси тарихына, аның Мәскәү белән булган мөнәсәбәтләренә күзәтү ясау белән беррәттән, татар халкының мәдәниятен, татар хатын-кызының җәмгыяттә тоткан урынын тәфсилләп яктырта, Россия хөкүмәте тарафыннан мөселман халыкларына карата алып барылган көчләп чукындыру сәясәтен тәнкыйтьләп чыга. Икенче докладта мөселман хатын-кызларының төрле тарихи чорларда җәмгыяттә тоткан урыннарын һәм мөселман илләрендә аларның хокукы өчен барган көрәшне яктырта. И.Ф.*Готвальд*, Н.Ф.*Катанов*, К.Насыйри, И.Н.Березин, В.В.Бартольд, Н.И.Веселовский, В.В.*Радлов*, И.Ю.Крачковский белән аралаша. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Л.Н.Толстой һ.б.ның

әсәрләрен төрек теленә, К.Насыйри төрек теленнән татар теленә күчергән «*Кабуснамә тәрҗемәсе*»н рус теленә (1886) тәрҗемә итә.



Гөлнар ханым (О.С.Лебедева)

Хезм.: Об эмансипации мусульманской женщины. СПб., 1900; Abrégé de l'histoire de Kazan // Offert aux membres du XII congres des orientalistes. Rome, 1899.

Әд.: Каримуллин А.Г. О.С.Лебедева — «Гульнар-ханум» // Народы Азии и Африки. 1977. № 3.

И.Х.Хәлиуллин.

ГРАММА́ТИКА (грек теленнән grammatikē, grammá — хәреф, язылыш), 1) тел төзелеше, ягъни тел формалары, сүз ясалышы һәм сүз үзгәреше ысуллары системасы; 2) тел белеменең тел төзелешен, аның оешуын, категорияләрен һәм аларның үзара мөнәсәбәтен өйрәнә торган тармагы; 3) аерым грамматик категорияләрнең яисә лексик-грамматик төркемнәрнең функцияләре (мәсәлән, исем грамматикасы, фигыль грамматикасы һ.б.). Дәреслекләрдәге һәм уку ярдәмлекләрендәге грамматик кагыйдәләр җыелмасы шулай ук грамматика дип атала.

Грамматика бер-берсе белән үзара бәйләнгән биш бүлектән — морфемика, морфонология, сүз ясалышы, морфология һәм синтаксистан тора. Сүзнең мәгънәле кисәкләренә караган гомуми үзенчәлекләрен морфемика бүлеге өйрәнә, грамматиканың башка бүлекләре өчен кереш хезмәтен үти, ул фонетика белән бәйле; сүзнең семантикасын өйрәнгәндә лексикология дә морфемика нәтиҗәләренә таяна. Морфемаларның сөйләмдә кулланылышы (хәрәкәте) вакытында аларның составында бара торган фонологик һәм просодик үзгәрешләрне өйрәнү белән морфонология шөгыльләнә, ул фонетика, фонология, морфология, синтаксис арасында тора, морфемика мәгълүматларыннан файдалана. Яңа сүзләр ясалу нәтиҗәсендә барлыкка килгән сүз структурасы системасын сүз ясалышы бүлеге анализлый, лексикология һәм морфология мәсьәләләрен берләштерә. Сүзнең абстракт грамматик мәгънәсенә һәм төрләренә бәйле барлык күренешләрне морфология бүлеге өйрәнә, ул шулай ук грамматиканың башка бүлекләре һәм лексикология белән дә тыгыз бәйләнештә тора. Җөмлә һәм сөйләм төзелешен синтаксис бүлеге тикшерә, башка бүлекләрнең нәтиҗәләрен туплый һәм, аларга нигезләнеп, сөйләмнең төп берәмлеге — җөмлә аша сөйләмнең структур төзелешен өйрәнә.

Татар грамматикасы фәне нигезләре гарәп грамматикасына караган хезмәтләргә барып тоташа. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан аның формалашуына рус теле белеме дә йогынты ясый. Татар теле грамматикасының фәнни эшкәртелүе С.Х.Хәлфиннең «Әлифба. Татар теле әлифбиенең тәхкыйк язылган хәрефләре һәм иҗекләре» (1778) хезмәте белән бәйле. Аннан соң И.И.Гиганов (1801), И.И.Хәлфин (1809), А.А.Троянский (1814), А.К.Казимбәк (1839), М.И.Иванов (1842) һ.б.ның хезмәтләре барлыкка килә.

Каюм Насыйри хаклы рәвештә хәзерге татар әдәби теленә нигез салучы санала. Галим: «Без — татарлар, телебез — татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул. Бөтен телләрдән бер дә ким түгел, эшләнмәгәнлек сәбәпле генә ул шулай артта калган», — дип, татар әдәби телен фәнни эшкәртү мәсьәләсен күтәреп чыга. Татар грамматикасын камил-

ләштерүдә К.Насыйриның хезмәтләре мөһим роль уйный. Ул 1860 елда, Казан руханилар семинариясендә татар теле укытучысы булып эшләгәндә, рус һәм татар телләрендә «Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах» китабын язып, Казан университеты басмаханәсендә нәшер итә. Кереш сүзендә: «Нәхү китабы. Урысча үгрәнүче татар егетләре өчен һәм вә татарча үгрәнүче урыс егетләре өчен тасниф кылдым Габделкаюм Габденнасыйр угылы», — дип күрсәтә. Татар лексикологиясе буенча русча-татарча «Лөгать китабы» сүзлеген (1892), шул ук елда фонетика һәм грамматика буенча «Кавагыйде китабәт» (1892) хезмәтен яза. 1895 елда морфология һәм синтаксис кагыйдәләре турында грамматика китабы — дүрт бүлектән (1. Кәлимә вә сүз (Авазлар һәм исемнәр); 2. Фигыльләр; 3. Хәрефләр; 4. Тәркиб вә тәсныйф кагыйдәләре (сүзләрне бәйләү чаралары)) торган «*Әнмүзәҗ*»не нәшер итә. Әлеге хезмәт «Әнмүзәҗ фи ән-нәхү» исеме белән 1910 елда кабат бастырыла.

Грамматика кагыйдәләрен татар теленең үзенчәлекләре белән бәйләп төзүгә омтылыш ясалган әлеге хезмәтне В.Х.*Хаков* 19 йөздәге иң яхшы татар грамматикасы буларак бәяли. М.З.*Зәкиев* К.Насыйриның милли телне камилләштерү буенча эшчәнлеген татар теле формалашуның теоретик мәсьәләләрен чишү, әдәби нормаларны билгеләүдә катнашу, аларны гамәлгә ашыру аспектларына бүлеп карый. Галимнең «Әнмүзәҗ» хезмәте һәм «Ләһҗәи татари» аңлатмалы сүзлеге йогынтысында Гыйбад Алпаров, Җамал *Вәлиди*, Галимҗан *Ибраһимов*, Мөхетдин *Корбангалиев*, Һади *Максуди*, Габдрахман *Сәгъди*, Нигъмәт Хәким һ.б.ның грамматикалары иҗат ителә, шулай ук 1930 еллардан татар грамматикасы өлкәсендә төп фәнни-тикшеренү юнәлешләрен билгеләгән В.А.Богородицкий, Латыйф *Җәлә́й*, В.Н.*Хангилдин*, Ф.С.*Фасиев* хезмәтләре дөнья күрә.

Әд.: Алпаров Г. Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан, 1925; Вәлиди Ж. Татар теленең грамматикасы. Казан, 1919; Җәләй Л.Ж. Каюм Насыйри (1825–1902) // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; шул ук. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри // Совет әдәбияты. 1945. №2; Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан, 1994; Ибраһимов Г. Татар сарыфы. Казан, 1911; Хангилдин В.Н. Каюм Насыйри грамматикаларында татар теле синтаксисы нигезләре // Совет әдәбияты. 1945. №2; шул ук. Татар теле грамматикасы: морфология буенча очерклар. Казан, 1954; шул ук. Татар теле грамматикасы. Морфология һәм синтаксис. Казан, 1959; Ахметгалеева Я.С. Каюм Насыри и татарская грамматика // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Батыршина Г.Г. Татарская грамматика Каюма Насыри // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы: материалы региональной научно-практической конференции, посвящённой 190-летию со дня рождения Каюма Насыри, Казань, 2015; Закиев М.З. К.Насыри и формирование современного татарского национального языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Хаков В.Х. Традиции К.Насыри в татарском языкознании. Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Хангильдин В.Н. Татарская грамматика Каюма Насырова «Энмюзяж» // Вопросы языкознания. 1956. №4.

И.Х.Хәлиуллин.

ГРИГО́РЬЕВ Василий Васильевич (15.03.1816, Санкт-Петербург –

19.12.1881, хәзерге Ленинград өлкәсенең Павловск шәһәре), шәркыятьче галим, Шәрекъ телләре докторы (1863), профессор (1863), Петербург Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1853).

Петербург университетын тәмамлаганнан соң, 1834–1836 елларда Россия Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында Шәрекъ телләре гыйльми бүлекчәсендә эшли. 1838–1844 елларда Одесса шәһәрендәге Ришелье лицеенда шәрекъ телләре укыта, фәнни максатларда Истанбул, Кишинёв шәһәрләрендә, Кырымда була. 1842 елда Мәскәү университетында «Алтын Урда ханнарының рус руханиларына биргән ярлыкларының чынлыгы хакында» темасына диссертация яклый. 1844–1880 елларда Тышкы эшләр министрлыгында хезмәт итә. 1851–1862 елларда — Оренбургта: Сырдәрья төбәгенә оештырылган поход вакытында яу канцеляриясе мөдире (1853), Оренбург чик буе комиссиясе рәисе (1854). 1863 елдан — Петербург университетында: Шәрекъ кафедрасы мөдире (1878 елга кадәр), бер үк вакытта, 1873–1878 елларда, Шәрекъ факультеты деканы. Россиядә беренче булып, Шәрекъ илләре тарихы буенча лекцияләр курсы укый.

1867 елда Рус археология җәмгыятенең Шәрекъ бүлеге идарәчесе итеп сайлана. «Правительственный вестник» басмасының мөхәррире була (1869). Соңрак — Матбугат эшләре буенча баш идарә җитәкчесе (1874–1880). 3 нче Халыкара шәркыятьчеләр конгрессын оештыручыларның берсе һәм аның рәисе (1876, Санкт-Петербург).

Хезмәтләре Россиядәге төрки халыкларның географиясенә, тарихы, этнографиясе, нумизматикасы, язма чыганакларына һәм Россия шәркыять фәне мәсьәләләренә карый. Ул Каюм Насыйриның фәнни эшчәнлегенә карата югары фикердә була. 1880 елда аның «*Император Рус география җәмгыяте язмалары*»нда дөнья күргән «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» мәкаләсенә кереш сүз сыйфатында урнаштырылган, 1868 елның 8 гыйнварына нисбәтле язмасында галимнең әлеге хезмәтен һәм аның шәхесен бәяләп: «Миңа мәгълүм булганча, Насыйров әфәнденең Казан татарларының ышанулары һәм йолалары хакындагы мәкаләсе — шул халыкның ислам кабул иткән өлешләрендә аларның хәзергәчә сакланган элекке дини ышанулары бәян ителгән тәүге тәжрибә. Мордваларның, чуашларның, Россиянең Европа өлешендәге башка җирле халыкларның мәҗүсилеге турында шактый күп мәгълүматлар тупланды, аларның беркадәре басылып та чыкты; әмма Насыйров әфәндегә кадәр һичберкем бөтен көнчыгыш Россиядә үзен нугайлар дип атаучы, без руслар арасында татарлар буларак мәгълүм кавемнең ислам бөркәнчеген ачып, аларның мөхәммәдилек кабыгы астында һаман да борынгы шаманлык эзләре саклануына күз салу турында уйлап та карамады. Шундый тикшеренүләр бик кирәк, алар фәнни табышларга өметләндерәләр. Мөселман татарлардан чыккан Насыйров әфәнде кебек күзәтүче моңарчы безнең арабызда булмады, мөгаен, барлык мөселман дөньясында да булмагандыр. Ул — Казан университетында алган европача белемнәре акыл җәһәтендә аны исламга объектив караш дәрәҗәсенә күтәргән беренче мөселманыбыз. Татарларны чагыштырмача яхшы ук белүемә карамас-



В.В.Григорьев


тан, андый күренешнең мөмкин булуы турында уйламаган да идем. Насыйров әфәнде күзәтүләр алып барган Казан мөселман татарларында, аның мәкаләсеннән күренгәнчә, шактый гына мөселманлык дәверенә кадәрге көнкүреш калдыклары саклана. Минемчә, христиан дине кабул иткән, «иске керәшеннәр» һәм «яңа керәшеннәр» дип аталган шундый ук Казан татарларында борынгы мәҗүсилек катламы күбрәк сакланган булса кирәк. Мордвалар, чуашлар һәм башкалар мисалыннан күргәнебезчә, ислам кысуына караганда, христианлык сүрүе астында аларда беренчел дини ышанулар ачыграк һәм җанлырак чагылырга тиеш. Шуңа күрә, Насыйров әфәнденең этнографик күзәтүләре дөирәсенә шул татарлар да керсә иде. Аның эйберләргә, мәсьәләләргә ничек бар шулай каравы яссылыгында фәнни тикшеренүләре мөселманлык җәһәтендә пропагандалауга шөбһә белдерүгә сәбәпче түгел», — дип яза.

Хезм.: Четырёхлетние археологические поиски в развалинах Сарая. СПб., 1847; Монеты афганских султанов Индии, найденные в развалинах Сарая. СПб., 1848; Описание Хивинского ханства и дороги туда из Сарайчиковской крепости. СПб., 1861; Предисловие / Насыров К. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на их жизнь суннитского магометанства // Записки Императорского Русского географического общества. По отделении этнографии / под ред. Н.И.Веселовского и П.И.Лерха. СПб., 1880.Т.6.

Әд.: Бартольд В.В. Материалы для истории факультета восточных языков. СПб., 1909. Т. 4; Веселовский Н.И. Василий Васильевич Григорьев по его письмам и трудам. 1816–1881. СПб., 1887; Крачковский И.Ю. Очерки по истории русской арабистики. М.–Л., 1950.

И.Х.Хәлиуллин.

«ГЫЙЛЬМӘ ҺӘНДӘСӘ» («Истыйлахате гыйльме һәндәсә» — «Геометрия фәне терминнары»), уку әсбабы. Геометрия фәне буенча Каюм Насыйри тарафыннан язылган һәм 1895 елда бастырылган күләме зур булмаган әсбап. Бу китапның максатын әдип менә шундый сүзләр белән аңлата: «Гыйльме һәндәсә дигәнмез җисем шөгыльләндергән фәраг мәүһүмнән [күз алдына китерелгән бушлык] бәхәс кыладыр. Бәс, ошбу җәһәттән җисем һәндәсә яки җисем тәгълими [җисемне өйрәнү] дип аталадыр ки. Ул шундаен җисемдер, һәр әтрафеннән ниһаятьләнмеш фәраг мәүһүмдер. Бер нәрсәгә бик озак карап торып күзебезне йомсак, гүяки күзебез алдында ул нәрсәнең сурәте калган кебек тоелыр. Бәс, җисме һәндәсә дигәнемез шуның төреннәндер».


(اصطلاحات علم هندسه)

بحث

هندسه فننده بر کچرلك کتابچه ابتدا

بحث


شاگردلرینه افاده اولمق تصنیف قیلدم

عبدالقیوم الناصری

کازان

К.Насыйри. «Гыйльме һәндәсә». Казан, 1895.

Китапта геометрик терминнарның, фигураларның, сызым өчен кулланыла торган әсбапларның атамалары китерелә. Сызымнарны башкару, төрле исәпләү ысуллары өйрәтелә. Ахырда



К.Насыйри. «Гыйльме һәндәсә» хезмәтеннән бер бит. 1895.

төрле геометрик фигураларның иллюстрацияләре бирелгән.

Чыг.: Насыйри К. Гыйльме һәндәсә. Казан, 1895.

Әд.: Фасеев Ф.С. Насыри и татарская терминология // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Р.Ф.Исламов.

ГЫЙЛЬМИ́ ҮЗӘ́К (Академүзәк), Татарстан Мәгариф халык комиссариатының структур бүлекчәсе. 1921 елда Мәгариф халык комиссариатының фәнни бүлеге нигезендә оештырыла. Татарстан Республикасындагы фәнни-тикшеренү, фәнни-педагогик, сәнгать, музей-архив, тәрҗемәчелек эшчәнлекләрен оештыру максатыннан төзелә.

Гыйльми үзәк фәнни-сәяси, фәнни-техник, фәнни-педагогик һәм сәнгать (бирегә шулай ук матур әдәбият, театр, музыка, сынлы сәнгать, кинематография бүлекләре керә) комиссияләреннән, ТАССР архив һәм музей баш идарәләреннән, секретариаттан тора. Аның эшчәнлеге белән рәис һәм биш кешелек коллегия җитәкчелек итә.

Җәмгыятьнең мәдәни тормышында барган зур үзгәрешләр чорында барлыкка килә. Ул республикадагы барлык фәнни, фәнни-оештыру һәм мәдәни-оештыру эшен үз җаваплылыгына ала. Аның эшчәнлегендә методик (уку-укыту планнары һәм программалары эшләү, методик мәсьәләләрне хәл итү), укыту (укытучылар әзерләү һәм аларның белемен күтәрү), тел белеме (татар телендә фәнни терминология булдыру, сүзлекләр төзү, тәрҗемәчеләр әзерләү), сәнгать (татар театрларының репертуарын контрольдә тоту һәм баету, татар музыкасын үстерү һәм популярлаштыру, музейлар, китапханәләр, түгәрәкләр эшчәнлеген активлаштыру, китап палатасы оештыру), фән (төбәк тарихын, монда яшәгән төрле милләтләр мәдәниятен, төбәкнең табигатен, иҗтимагый, икътисади үсешен өйрәнү, тарих, археология, этнография, филология фәннәрен үстерү), борынгы һәйкәлләрне, мәдәни мирасны саклау һәм өйрәнү юнәлешләренә аеруча әһәмият бирелә. Гыйльми үзәк карамагында шулай ук татар халкын гыйльми өйрәнү оешмалары («Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте», «Татарстанны гыйльми өйрәнү җәмгыяте», «Татар мәдәнияте йорты» һ.б.) эшли. Ул шулай ук татар театры һәм музыка сәнгатен үстерүгә багышланган беренче дәүләт чараларын үткәрә.

Аеруча уңышлы эшләгән вакыты атаклы язучы һәм галим Галимҗан *Ибраһимов* рәислек иткән чорга туры килә; аерым алганда, Каюм Насыйрины искә алу юнәлешендә төрле чаралар гамәлгә ашырыла. 1922 елның 13 июнендә К.Насыйриның вафатына 20 ел тулуга багышлап, Гыйльми үзәк татар редакциясе коллегиясенең Гаяз

Максудов рәислегендә, Галимҗан Ибраһимов, Газиз *Ғобәйдуллин*, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гали *Рәхим* һәм Н.Абызов катнашында уздырылган утырышында Г.Ибраһимов доклад ясый. Әлеге чыгыштан соң К.Насыйриның биографиясен өйрәнү һәм аның хакында материаллар туплау максатында Тәтеш шәһәренә һәм Зөя кантонының Югары Шырдан авылына берничә кеше җибәрү, Г.Гобәйдуллинга һәм Г.Рәхимгә К.Насыйриның аерым хезмәтләрен җыюны йөкләү һәм башка эшләр турында карар кабул ителә. Гыйльми үзәк 1922 елның 2 сентябрендә К.Насыйриның вафатына 20 ел тулуга багышлап искә алу көне үткәрергә карар кабул итә; Г.Ибраһимов рәислегендә С.Атнагулов, Г.Гобәйдуллин кергән өч кешелек оештыру комиссиясе төзелә, ул галим хакында махсус җыентык әзерләү эшен башлый. Басма («Каюм Насыйри мәҗмугасы...») шул ук елда дөнья күрә.

1925 елның 10 февралендә Гыйльми үзәкнең татар редакциясе коллегиясе утырышы була. Анда түбәндәге карар кабул ителә: «1) Йөз ел тулган көнне Каюм Насыйриның шәхесе белән киң катлауны таныштыру, аның ролен ачыклау һәм хезмәтләрен барлау максатында зур ачык җыелыш уздырырга. 2) Журналистика институтында Каюм Насыйри исемендәге стипендия булдыру хакында ТАССР Мәгариф халык комиссариаты коллегиясенә юллама белән мөрәҗәгать итәргә. 3) 4 нче Евангелистлар урамы атамышын Каюм Насыйри исеменә алыштырырга. Бу көнне билгеләп үтү өчен тиешле оешмаларга мөрәҗәгать итәргә. Йөз ел тулу көнен билгеләп үтү өчен комиссия төзүне Академүзәккә йөкләргә. Программаны нигездә кабул итәргә, аны детальләштерүне һәм үткәрүне шул ук комиссиягә тапшырырга».

1925 елның 15 февралендә Гыйльми үзәк тарафыннан Татар дәүләт театры бинасында Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулу уңае белән юбилей кичәсе уздырыла. Анда Галимҗан Ибраһимов (Гыйльми үзәк рәисе, кичәне ача һәм алып бара), ТАССР мәгариф халык комиссары Шәһит *Әхмәдиев* (республика хөкүмәтенең котлау хатын укый), Әхмәтһади *Максуди*, Фатих *Әмирхан*, Мөхәммәт *Парсин*, Мөхетдин *Корбангалиев*, Гали Рәхим, Заһид Нуркин, Хәйретдин Вәлиев, Нәкый *Исәнбәт* һәм башка күренекле фән, мәдәният һәм җәмәгать эшлеклеләре катнаша. Г.Ибраһимов «Каюм Насыйриның тарихи роле», М.Парсин «Насыйриның биографиясе», М.Корбангалиев «Насыйриның имля, әдәби тел турында хезмәтләре» дигән темаларга докладлар ясыйлар. Татарстан хөкүмәте исеменнән чыгыш ясаган Ш.Әхмәдиев Татарстан Җөмһүрияте Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Шәйгәрдан *Шәймәрданов* һәм Халык Комиссарлары Советы рәисе Хаҗи *Ғабидуллин* имзалаган котлау хатын укый, Каюм Насыйри исемен мәңгеләштерү юнәлешендә түбәндәге эшләрне башкарырга карар кылыну хакында хәбәр итә: «1) Мәскәүдә Журналистлар институтында Насыйри исемендәге стипендия билгеләргә; 2) Татар тәгълим-тәрбия техникумын Насыйри исеме белән атарга; 3) Казанда Евангелистовский һәм Яңа Бистәдә Большой Симбирский урамнарын Насыйри урамы дип атарга; Насыйри әсәрләрен сайлап бастырырга».

ТАССР Мәгариф халык комиссариатының 1925 ел 24 февраль карары нигезендә Татар педагогия техникумына Каюм Насыйри исеме бирелә. Гыйльми үзәкнең 1925 ел 26 март утырышында ТАССР Халык Комиссарлары Советы күрсәтмәсе буенча Ка-

юм Насыйриның 100 еллыгына җыентык әзерләп чыгару турында кабул ителгән карар гамәлгә ашырыла: җыентык 1926 елда дөнья күрә.

Әд.: Әмирхан Ф. Бу рухта беренче... // Безнең юл. 1925. № 3; Гыйльми үзәктә // Безнең юл. 1925. №5; Гыйльми үзәктә // Мәгариф. 1925. №3; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга / Гали Рәхим карамагында. Казан, 1926; Фаттахова Г.А., Валеев Р.К. Академический центр Татарии в 1920-е годы. Казань, 2002; Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов. Казань, 1977.

И.Х.Хәлиуллин.

ГЫЙМАДЕТДИ́НОВ Хәйретдин Гыймадетдин улы, кара: *Гыймади* Хәйри.

ГЫЙМАДИ́ Хәйри (Гыймадетдинов Хәйретдин Гыймадетдин улы) (01.09.1912, Казан губернасының Зөя өязе (хәзер Яшел Үзән районы) Мулла Иле авылы – 11.10.1961, Казан), тарихчы, тарих фәннәре кандидаты (1949).

Казан педагогия институтын тәмамлый (1932). 1927–1930 елларда Зөя һәм Казан басмаханәләрендә хәреф җыючы булып эшли. 1932–1943 елларда — Казан педагогия институтында: 1941–1942 елларда — тарих факультеты деканы, бер үк вакытта Казан университетында укыта. 1945 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында: 1946–1959 елларда — тарих секторы мөдире. «Татарстан АССР тарихы»н (1–2 т., 1955–1960) нәшер итүдә катнаша: 1 нче томның җаваплы мөхәррире, татарларның килеп чыгышына, болгар халкы тарихына, рухи мәдәнияткә, иҗтимагый хәрәкәтләргә һ.б.га багышланган бүлекләрне әзерли.



Х.Г.Гыймади

Хезмәтләре Алтын Урда, Татарстан тарихына, татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләренә карый. 1948 елда, К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган фәнни сессия материалларын туплап, рус телендә нәшер ителгән җыентыктагы «Каюм Насыйровның тарих-археология материаллары җыю өлкәсендәге хезмәтләре хакында» мәкаләсендә галимнең, башлыча тел белгече булуына карамастан, фәннең башка тармакларын да өйрәнүе, шул исәптән тарих һәм археология мәсьәләләре күтәрелгән уннан артык хезмәт язуы, аларның бер өлеше галим тарафыннан чыгарылган «Казан календаре»нда, соңрак 1926 елда дөнья күргән «Каюм Насыйриның басылмаган әсәрләре» җыентыгында урын алуы, К.Насыйриның татарлар арасында рус тарихын популярлаштыруга беренче булып алынуы, шул юнәлештә башлап «Россиянең кыскача тарихы»н төзүе турында әйтелә; аның «Казан тарихы буенча материаллар», Казан губернасы Зөя һәм Чуел (Цивильск) өязләре авылларын йөреп чыкканда җыелган халык авыз иҗаты әсәрләре (тарихи риваятьләр, җырлар, бәетләр), үзе шәхсән өйрәнгән кулъязма китаплардагы, борынгы кабер ташларындагы мәгълүматлар нигезендә барлыкка килгән «Археология материаллары», Казан сәүдәгәре, һәвәскәр тарихчы Мөхәммәтҗан Аитов хәбәрләре дә кергән «Лука Каратун, Пугачёв, Ишбулат мулла турында», «Рус тарихының берничә сә-

хифәсе», «Россиянең кыскача тарихы» әсәрләре күздән кичерелә һәм аларга бәя бирелә; галимнең әлеге юнәлештәге тикшеренү алымнары һәм ысуллары бәян ителә.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.


Хезм.: Народы Среднего Поволжья в период господства Золотой Орды // Материалы по истории Татарии. Казань, 1948. Вып. 1; О трудах К.Насыри в области собирания историческо-археологических материалов // Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвящённых 120-летию со дня рождения). Казань, 1948; Употребление термина «татары» // Вопросы истории. 1954. № 8.

И.Х.Хәлиуллин.

ГЫЙММА́ЕВ Зөфәр Фоат улы (09.01.1951, Үзбәкстан ССРның Нәманган шәһәре – 15.02.2022, Казан), нәкышьче, Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980), ТР Рәссамнар берлеге рәисе (2008–2020). ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2002), РФнең атказанган рәссамы (2012), ТРның халык рәссамы (2017), ТР Мәдәният министрлыгының Бакый Урманче бүләгә (2003), Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге (2005) лауреаты.

Казан сынлы сәнгать училищесын (1970), И.Е.Репин исемендәге Ленинград нәкышь, скульптура һәм архитектура институтын (1976, А.Д.Зайцев остаханәсе), СССР Сәнгать академиясенең Казандагы Х.Г.Якупов җитәкчелегендәге нәкышь иҗат остаханәсен (1980) тәмамлый. 1976–1978, 1982–1984 елларда Казан сынлы сәнгать училищесында укыта. Бер үк вакытта, 1980 елдан, Татарстан Сәнгать фондында эшли.

Тематик картина, портрет, пейзаж, натюрморт жанрларында уңышлы эшли. «Әбигә хат килде» (1979), «Кичке автобуста» (1980), «Өч ай» (1997) картиналары тирән тәэсирле эчтәлек, лиризм белән сугарылган. З.Гыймаев иҗатында портретлар, шул исәптән төркемле портретлар зур урын алып тора. Шәхесләрнең тышкы охшашлыгына ирешү белән беррәттән, рәссам аларның эчке дөньясын тирәнтен чагылдыру, катлаулы фонда дөрес сайланган аксессуарлар ярдәмендә төгәл һәм үзенчәлекле композиция төзү осталыгына ия («Татарстан акробатлары», 1979; «Икәү чәй эчү. Язучы Фәнис Яруллин һәм аның хатыны Нурсөя ханым», 2000).




З.Ф.Гыймаев

З.Гыймаев — психологик портрет остасы. Ул үзенең кылкаләме белән героеның эчке халәтен, уй-кичерешләрен буяулар аша зур осталык белән ачып бирә. Аның портретларында гәүдә тотышы, күз карашы, куллар — барысы да әһәмияткә ия. Ул татар артистлары, режиссёрлары, драматурглары, язучылары портретлары сериясен тудыра («Гаяз Исхакый», 1993; «Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская», 1993; «Кәрим Тинчурин һәм Салих Сәйдәшев», 1993; «Рәфкат Бикчәнтәев», 1994; «Нәкый Исәнбәт», 1995; «Туфан Миңнуллин», 1995; «Кәшифә Тумашева», 1999; «Гали Надрюков», 1999; «Гали Ильясов», 1999; «Дамир Сиражиев», 2001; «Празат Исәнбәт», 2002; «Марсель Сәлимҗанов», 2006). «Күкидә кич» (1978), «Өмбе авылында көз» (1982) лирик пейзажлары, «Татар сөлгесе белән натюрморт», «Иске кофе савыты белән натюрморт» (икесе дә — 1978) авторы.

Каюм Насыйри музеенда сакланучы «Каюм Насыйри» портреты З.Гый-

маев тарафыннан 2001 елда иҗат ителә. К.Насыйриның фоторәсеме булмаганлыктан, аның портретын рәссам төрле чыганаклардагы истәлекләргә таянып яза. Бөек мәгърифәтче кулына китап тоткан хәлдә сурәтләнә. Китап тышына гарәп хәрефләре белән иске татар телендә «Әнмүзәҗ» дип язылган. Рәссам портрет аша К.Насыйри өчен иң мөһим мәсьәләләрнең



З.Ф.Гыймаев.
«Каюм Насыйри» портреты.
Киндер, майлы буяу. 2001.

берсе булган белем тарату омтылышын күрсәтеп бирә.

Бөтенсоюз, бөтенроссия, төбәкара һәм республика күргәзмәләрендә (1970 елдан), Төркия (1991 елдан) һәм Словакиядә (1994 елдан) узган халыкара күргәзмәләрдә, «Тюрксой» 3 нче халыкара пленэрында (Төркия, Анталия шәһәре) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1998 (Словакия, Снин шәһәре), 1995, 2001 (Казан), 2002 (Яшел Үзән шәһәре) елларда уза.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, В.Суриков исемендәге сынлы сәнгать музеенда (Красноярск шәһәре), Пермь картиналар галереясында, Салих Сәйдәшев исемендәге музейда, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында, Татар академия театрында, шулай ук Польша, Словакия, Чехия, Германия, Төркия, Франция, Англия, Израиль, АКШ һәм башка илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

Әд.: Колина С. Освещённые солнцем // Казань. 2002. №5; Новицкий А. Один из лучших мастеров // Казань. 2002. №5; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. Казань, 1984.

М.Е.Ильина, Ф.Г.Камальтдинова.

Д

«ДЕ́ЯТЕЛЬ», иҗтимагый-әдәби журнал; Казан аеклар җәмгыяте органы. 1896 елның гыйнварыннан 1917 елга кадәр Казанда айга (кайбер очракта — ике айга) бер тапкыр рус телендә нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре һәм наширләре — Казан аеклар җәмгыяте рәисләре А.И.Александров, А.Т.Соловьёв. Җәмгыять әгъзалары — Казан университеты һәм Казан руханилар академиясе укытучылары һәм профессорлары Е.Ф.Будде, А.Ф.Гусев, Л.О.Даркшевич, И.М.Догель, В.Ф.Залесский, М.Я.Капустин, Н.Ф.Катанов, Ф.Г.Мищенко һ.б., шулай ук руханилар Е.Ф.Сосунцов, В.А.Охотин хезмәттәшлек итәләр һәм материалларын бастыралар.

Журнал битләрендә аек тормыш итү мәсьәләләре пропагандалана. Спиртлы эчемлекләр белән сату итүгә кагылышлы хөкүмәт карарлары, аеклар җәмгыятенең җыелыш беркетмәләре, аның бүлекләре эше турындагы хисап материаллары, Россия һәм чит илләрдәге аеклар җәмгыятьләре һәм хәйрия оешмаларының эшләре турында мәгълүмат, бакчачылык, яшелчәчелек, умартачылык һәм башка һөнәрләр белән шөгыльләнүчеләргә киңәшләр басыла. Россиядә шәраб ясау һәм сатуга дәүләт монополиясе кертүнең барышына йомгак ясала. Рухи-әхлакый, юридик, икътисади, педагогик, медицина-санитария мәсьәләләренә, эчкечелек һәм тәмәке тартуны бетерүгә кагылышлы материалларга зур урын бирелә.

Журналның «Шәрекъ библиографиясе» бүлеге укучыларны татар мәдәнияте белән таныштыруда әһәмиятле роль уйный (күпчелек мәкаләләрнең авторы — Н.Ф.*Катанов*), шушы бүлек эшеннән татар китапларының библиографиясен төзү башланып китә. Аннотация һәм рецензияләрдә китапның басылу урыны, вакыты, күләме турында мәгълүмат, автор һәм әсәрдә урын алган шәхесләр турында биографик белешмәләр, Россиянең төрле шәһәрләрендә яшәүче татарлар арасында китап тарату турында мәгълүматлар китерелә. «Шәрекъ библиографиясе» бүлегендә татар зыялылары, шул исәптән Каюм Насыйри хезмәтләрен тасвирлауга аерым игътибар юнәлтелә. Н.Ф.Катанов галимнең «Кавагыйде лисане гарәб» («Гарәп теле грамматикасы») (1897, № 2), «Кабуснамә тәрҗемәсе» (1898, № 5), «Әхлак рисаләсе» (1898, № 5), «Китап әт-тәрбия» («Тәрбия китабы») (1898, № 6–7), «Җәваһир әл хикәят» («Хикәяләрнең җәүһәре») (1898, № 8–9), «Санаигы голфания» («Гальваника эшләре») (1901, № 5) әсәрләренә югары бәя бирә.

1905–1907 еллардагы революция вакытында журналның юнәлеше кискен үзгәрә; ул «Православие, самодержавие, халыкчанлык» шигаре астында чыга башлый. Россия Дәүләт Ду-

масына тискәре карашлы мәкаләләр күренә, монархиячел, карагруһчылык карашлары пропагандалана. Шуның өчен журнал Казанда чыга торган башка газеталар тарафыннан тәнкыйтьләнә. Казандагы монархиячел партияләрнең үз басма органнары барлыкка килгәч, басма баштагы тематикасына кире кайта. Журнал Казан аеклар җәмгыяте китапханәләренә җибәрелә һәм, башлыча, Казан губернасы авылларында таратыла.



ДѢЯТЕЛЬ

№ 11.

НОЯБРЬ

1900.

КАЗАНЬ.
Типо-литографія Императорскаго Университета.
1900.

«Деятель» журналы.

Әд.: Каримуллин А.Г. Книги и люди. Казань, 1985; Катанов Н.Ф. Книга «Кавааиди-лисани-араб» («Правила арабского языка») // Деятель. 1897. №2; шул ук. «Кабус-наме терджемесе» (Перевод книги «Кабус-наме»// Деятель. 1898. №5; шул ук. «Ахляк рисалесы» («О нравственности») // Деятель. 1898. №5; шул ук. «Тербия китабе» («Книга воспитания») // Деятель. 1898. №6–7; шул ук. «Джауагируль-хикаять уа ль-асъиле уа лятаифур-риуаять уа ль-амсиле» («Драгоценности рассказов и вопросы остроумия предания и притчи») // Деятель. 1898. №8–9; шул ук. «Санаи гальфание» («Работы гальванические») // Деятель. 1901. №5.

И.Х.Хәлиуллин.

ДИНИ́ ГЫЙЛЕ́М, пәйгамбәрләр мирасы. Татар халкы көндәлек тормышына дини гыйлемне өйрәнү традицияләре Идел буе Болгар дәүләте чорыннан керә башлый, һәм ул Алтын Урда, Казан ханлыгы заманнарында яңа үсеш ала. 18–19 йөзләрдә дини гыйлем тарафдарлары ислам диненең догматикасын, тарихын, мәдәниятен, хокукын, мөселман халыкларының икътисадын һәм башка тармакларын өйрәнәләр һәм исламның рухи кыйммәтләре һәм ориентирлары аларга ялгыш булмаган мәгълүмат чыганагы булып хезмәт итә.

Каюм Насыйри, ислам дине тарафдары буларак, мөселман йолалары, әхлагы һәм ислам тәгълиматын өйрәнүгә һәм таратуга зур өлеш кертә. Әдип Аллаһны һәм фани дөнья мөнәсәбәтләрен деизм (икелек) фәлсәфәсе карашыннан торып аңлата. Аныңча, җиһандагы тәртип, табигать күренешләренең агышы Аллаһ тарафыннан билгеләнә, ләкин ул әлеге агыш-күренешләргә турыдан-туры катнашмый. К.Насыйри: «Бу дөнья — сәбәпләр дөньясы. Без мохтаҗ булган бар нәрсә билгеле бер сәбәпкә бәйле. Әлеге сәбәпләрне уй-фикер йөртеп, акыл белән эзләнеп кенә аңлап-белеп була. Күренешләрнең сәбәбен белергә һәм шуларга таянып хәрәкәт итәргә кирәк», — дип яза. Димәк, аның фикеренчә, бу дөньяда кеше язмышка буйсынырга түгел, сәбәпләлек мәсьәләсенә таянып хәрәкәт итәргә, күренешләрнең сәбәбен аңларга һәм шуңа бәйле көчләрне кеше файдасына эшләтергә тиеш. Ул фәннең һәм кеше акылының дөньяны танып белүдәге һәм күренешләрнең сәбәпләрен ачыклаудагы урынына аеруча зур басым ясый, җан азыгы өчен Аллаһны тану, барлау һәм зурлау зарур булса, тормыш өчен гыйлем, акыл, белем, тәҗрибә зарур-

лыгы мөһим, кеше бу дөньяда җан һәм акыл берлегендә яшәргә тиеш, дип исәпли. Әлеге фикерне аның тормышны, табигатьне һәм кешенең тормыштагы урынын аңлаудагы иң алдынгы карашларының берсе дип бәяләргә мөмкин.

Галим ислам дине, мөселман тәгълиматы һәм Коръән белгечлеге өлкәсенә караган хезмәтләр дә яза. Кайбер мәгълүматлар нигезендә ул бу эшкә Казан руханилар семинариясендә укучыларга Евангелиене татар телендә укыткан вакытта керешә дигән фараз бар. Мәгърифәтче 1859 елда мөселман дине тәгълиматы турында «Гакаид исламия» дип аталган китап яза. Китап 1867 елда гына дөнья күрә (тулырак кара: «*Гакаид рисаләсе*»). К.Насыйриның ислам гыйлеменә караган берничә хезмәте, шулар арасында «Мохтәсар тәварих әнбия» (1884), «Мәҗмәгу әл-әхбар» (1891) даими рәвештә бастырыла. Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә аның ислам диненә караган «Пәйгамбәрләр шәҗәрәсе», «Төрле вәгазьләр», «Утыз вәгазь», «Мохтәсар тәварих әнбия», «Ислам дине вәкилләренең биографиясе», «*Мифтах әл-Коръән*» һәм башка кулъязмалары саклана.

К.Насыйриның Коръән белгечлегенә караган «Мифтах әл-Коръән» хезмәте аерым әһәмияткә ия. Автор, аны дүрт ел буе эшләп, кулъязмасын 1886 елда тәмамлый. Ул үзенең әлеге хезмәтен фәнгә иң күп көч биргән «җимеш»е буларак бәяли, «Мифтах әл-Коръән» һәр белгечкә Коръән белән Коръән-хафиз дәрәҗәсендә эшләргә мөмкинлек бирәчәк дип исәпли. Аңа алынганда галим, мөселманнарга Коръәннән файдалануны һәм аны өйрәнүне җиңеләйтү ниятендә, Коръәннең алфавит буенча төзелгән лексик берәмлекләренең махсус сүзлеген булдыру максатын куя. К.Насыйригача кадәр мондый эшне ике генә галимнең башкаруы билгеле. Хезмәтләрнең берсе — немец галиме Густав Флюгель сүзлеге (1842), икенчесе — Казан университеты галиме Мирза Казимбәк (А.К.Казимбәк) сүзлеге (1859). К.Насыйриның хезмәтебернигә кадәр Европа исламият гыйлеменә тартым булса да, әлеге сүзлекләрдән аерылып тора. Кечкенәдән үк Коръәннең кыйммәтен аңлап үскән, шул рухта тәрбияләнгән галим Коръәннең фәлсәфәсен саклап кала, һәрбер гыйбарәне Коръәннең ачкычы буларак күзаллап, «Мифтах әл-Коръән» хезмәтен үзенчәлекле методика белән төзи. К.Насыйри кулъязмага кереш сүзендә: «Мин нәшер итәргә телим һәм аның белән бергә әле мин Коръән дә нәшер итәм, чөнки алар икесе бергә баралар», — дип белдерә. Шул рәвешле, кулъязма һәм «Каләм шәриф» (Коръәннең Казан басмасының ул вакыттагы атамасы) икесе бергә нәшер ителәләр.

Әд.: Әл-Хуҗаши Н. Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри илә мөсхабә (хатирә дәфтәрләремнән) // Шура. 1912. №24; К.Насыйри. Мифтах әл-Коръән. 2 томда / төз., транслитерация һәм тәрҗемә итүче, кереш сүз авторы А.Г.Хәйретдинов; кереш мәкалә авторы Р.Ф.Шәфигуллина. Казан, 2015.

Р.В.Шәйдуллин.

ДМИ́ТРИЕВ Николай Константинович (16.08.1898, Мәскәү – 22.12.1954, шунда ук), тел галиме-тюрколог, филология фәннәре докторы (1938), СССР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1943), РСФСР Педагогия академиясе хакыйкый әгъзасы (1945), Башкортстан АССР (1947), Төрекмәнстан ССР (1950) һәм Чуаш АССРның (1953) атказанган фән эшлеклесе. Совет тюркология мәктәбенә нигез са-

лучыларның берсе, милли республикаларда, шул исәптән Татарстанда төркология фәнен үстерүгә өлеш керткән галим.

Мәскәү университеты тарих-филология факультетының классик һәм славян бүлекләрен (1920), СССР Фәннәр академиясе Мәскәү көнчыгышны өйрәнү институтының төрек, фарсы һәм гарәп разрядларын (1922) тәмамлый. 1925 елдан — Ленинград җанлы Көнчыгыш телләре институтында (1929–1938 елларда — профессор, 1930 елдан — төрек теле кафедрасы мөдире); бер үк вакытта, 1926 елдан — Ленинград университетында (1930 елдан — профессор, 1944–1948 елларда — төрки филология кафедрасы мөдире); бер үк вакытта, 1926–1932 елларда — Көнчыгыш һәм Көнбатыш халыклары әдәбиятын һәм телләрен чагыштырып өйрәнү фәнни-тикшеренү институтында, 1928 елдан — Мәскәү университетында (1929 елдан — профессор, 1930–1939 елларда — төрки телләр кафедрасы мөдире, 1940–1942 елларда — төрки филология кафедрасы мөдире, 1943 елдан — филология факультетының Шәрекъ бүлеге мөдире); бер үк вакытта, 1938–1954 елларда — СССР Фәннәр академиясе Тел белеме институтының төрки телләр бүлеге мөдире.

Төрки телләрне системалы тасвирлый, төрки һәм славян телләренең үзара бәйләнеш тарихын, тел тарихының мөһим чыганагы сыйфатында фольклорны, татар телен өйрәнә, аны башкорт, чуаш һәм рус телләре белән чагыштырып тикшерә. Каюм Насыйри иҗатын анализлый һәм аңа югары бәя бирә. 1945 елда Казанда К.Насыйриның 120 еллыгына багышлап уздырылган фәнни сессиядә катнаша. Ул К.Насыйригa багышланган рус һәм татар телләрендәге чыгышларында галим-мәгърифәтченең грамматика, лексика, морфология, әдәбият белеме, фольклор, сүзлекләр төзү өлкәләрендәге хезмәтләренә тирән күзәтү ясый, сүзлекләр төзү методикасын тикшерә, аны М.В.Ломоносов, Леонардо да Винчи белән чагыштырып, аларның барысының да уртаклыгын — энциклопедик фикер ияләре булуын, аерым фән яки сәнгать төре кысаларында калмауларын, яшәешләре дәвамында тормыш тарафыннан таләп ителгән барлык фәннәргә һәм сәнгать төрләренә нигез салып калдырырга омтылуларын ассызыклый.



Н.В.Дмитриев

Н.Дмитриев К.Насыйри шәхесенә карата зур ихтирам белән: «Каюм Насыйри татар халкы тарихының феврале дип атарга мөмкин булган бер чорда дөньяга килгән. Татар урта гасырыннан яңа вакытка күчүнең бер чорында һавада культура язының һәм уянып күтәрелүнең чаткылары сизелә иде, дөресен әйткәндә, Каюм Насыйри үзе шушы язның хәбәрчесе иде. Ислам һәм мөселман схоластикасы тәэсире астында яшәгән иске татар дөньясыннан чыгып, ул әкрен генә, ләкин ышанычлы адымнар белән яңа юлга аяк басты. Әгәр дә Каюм Насыйри шагыйрь яки язучы булган булса иде, ул, әлбәттә, яңа тормыш өчен көрәш турында ялкынлы шигырьләр һәм шул көрәшне чагылдыра торган ачык образлар калдырып киткән булыр иде. Әгәр ул политик эшлекле булган булса, шул вакытта ул үзе — язучы каләме астында шундый образларның берсе итеп чагылдырылган булыр иде. Ләкин тыйнак укытучы, тәрҗемәче һәм китаплар чыгарып таратучы булган Каюм Насыйри алгы планга чыга

белмәде һәм чыга да алмады, ул үзенең тәвәккәл һәм тирән идеяләрен азларга гына билгеле булган хезмәт яратучы бер кеше сыйфатында көндәлек тормышында үткәреп килде. Аның өчен яңа юл татар мәгарифен көнчыгыштан көнбатышка борып җибәрүдән, бу мәгарифнең түгәрәген электә искә алынмаган физика, химия, география, табигыять фәне шикелле дөньяви фәннәр хисабына киңәйтүдән, татар халкы массасы арасында белем чаткылары таратудан гыйбарәт иде... Каюм Насыйри образы татар культурасы һәм мәгарифенең бөтен халык белергә тиешле иң мөһим эшлеклеләре галереясына керергә тиеш. Татар һәм рус телләренең бәйләнеше турындагы аның төп фикере безнең өчен җитәкче фикер булып торырга тиеш. Татар халкы үзенең мәгърифәтчесе белән горурланырга тиеш. Татар халкыннан чыкмаган була торып та аның культурасын ихтирам итә белүчеләр исә яктылык һәм белем өчен шулкадәр бирелеп көрәш алып барган Каюм Насыйри истәлеге алдында баш ияргә тиешләр», — дип яза. Шулай ук ул Каюм Насыйрины «татар халкының яз хәбәрчесе», «татар мәгарифен шәрекътән көнбатышка таба борган кеше» дип атый.

Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Филолог буларак Каюм Насыйри // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Строй турецкого языка. М. 1939; Грамматика кумыкского языка. М., 1940; Грамматика башкирского языка. Л., 1948; Каюм Насыйри как филолог // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвящённых 120-летию со дня рождения). Казань, 1948. Строй тюркских языков. Сб. избр. трудов. М., 1962.

Әд.: Аракин В.Д. Николай Константинович Дмитриев (1898–1954). М., 1972; Николай Константинович Дмитриев: К 100-летию со дня рождения М., 2001.

И.Х.Хәлиуллин.

ДОМБРО́ВСКИЙ Б.Л. БАСМАХАНӘСЕ́, Казандагы хосусый басмаханә. 1894 елда элегрәк китап басу эше белән шөгыльләнмәгән теш табибы Б.Л.Домбровский барлык җиһазлары белән Г.М.Вечеслав басмаханәсен сатып ала. Ул полиграфия басмаларының сыйфатлы башкарылуын тәэмин итүче белемле хезмәткәрләрне үзләренең эш урыннарында калдыра. 1898 елда басмаханәдә 38 хезмәткәр эшли. 1894–1900 елларда анда татар телендә 1,5 млн тираж белән 173 исемдә китап, башлыча, әлифбалар, уку китаплары, татар халык авыз иҗаты әсәрләре, Һади Максуди, Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Каюм Насыйри һ.б.ның хезмәтләре, әсәрләре, дәреслекләре һәм дини-әхлакый эчтәлекле китаплар нәшер ителә. 1910 елда басмаханәдә Казан өязе Түбән Әйшә авылы кешесе, китап сатучы Исмәгыйль Шәмсетдинов акчасына К.Насыйри тарафыннан иске төрек (госманлы) теленнән тәрҗемә ителгән «Кырык вәзир кыйссасы»ның 160 битле 8 нче басмасы дөнья күрә.

Совет хакимияте тарафыннан дәүләт милкенә алына.

Әсәр.: Кырык вәзир кыйссасы (Госманлы теленнән тәрҗемә кыйлынып Казанда сигезенче мәртәбә басылды. Габделкаюм мулла Габденнасыйр углының тәрҗематеннәндер). Казан, 1910.

Әд.: Домбровский Б.Л. басмаханәсе // Татар энциклопедиясе: 6 томда. Казан, 2010. 2 т.; Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. Казань, 1974; шул ук. Татарская книга пореформенной России. Казань, 1983.

И.Х.Хәлиуллин.

ДУСА́ЕВ Гатаулла (1887, Казан губернасының Зөя өязе Югары Шырдан авылы (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы) – ?), колхозчы, Каюм Насыйриның авылдашы һәм аның турында истәлек сөйләүче.

Авыл мәктәбендә башлангыч белем ала. Крестьян, колхозчы хезмәте белән көн күрә. 1923 елда Кече Шырдан авыл советы секретаре вазифаларын башкара.

К.Насыйрины күреп белә. Мәктәптә укыган елларында галимнең авылга кайтып йөрүен, аның янына мөнәҗәтләр әйтергә йөргәнен хәтерли. «Без мөнәҗәт әйткән вакытта, ул кызыксынып, кет-кет көлеп утыра иде. Мөнәҗәт-такмак әйтеп бетергәч, ул безгә 5–10 тиен акча бирә иде», – дип истәлекләре белән уртаклаша. Аның авыл мәктәбенә җәдит укуы кертүче дә булуын әйтеп уза. Г.Дусаевның К.Насыйри турындагы истәлекләрен 1945 елда фольклорчы Хәмит *Ярми* язып ала. Бу истәлек-хатирә 1948 елда К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган җыентыкта бастырыла. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Ф.Г.Камальтдинова.

ДҮРТ ЙӨЗ УНБИШЕНЧЕ́ БАЛАЛА́Р БАКЧАСЫ́, муниципаль автономияле мәктәпкәчә татар телендә тәрбия һәм белем бирү оешмасы. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2003).

Казан шәһәренең Совет районында урнашкан. 1961 елда 13 нче ясле-бакча буларак төзелә. 1997 елда 95 балага исәпләнгән, татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 415 нче балалар бакчасы буларак ачыла. 5 төркем: 1 нче кечкенәләр (2–3 яшьтәгеләр), 2 нче кечкенәләр (3–4 яшьтәгеләр), уртанчы (4–5 яшьтәгеләр), зурлар (5–6 яшьтәгеләр), әзерлек (6–7 яшьтәгеләр) төркемнәре, алар белән 8 укытучы эшли (2024 ел).

Эшчәнлегендә балаларда мәдәнияткә, халык традицияләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү аша туган телгә (татар теленә) карата мәхәббәт, милли үзаң, әхлакый кешелек сыйфатлары формалаштыруга юнәлеш тота. К.Насыйри иҗатында милли тәрбия, халык педагогикасы мәсьәләләре киң чагылыш табу сәбәпле, педагоглар мәгърифәтченең әсәрләрен, шулай ук аның халыктан жыеп, туплап, эшкәртеп чыгарган, зур тәрбияви әһәмияткә ия әкиятләрен файдаланалар. Әкиятләр балаларның яшь үзенчәлекләренә яраклаштырыла, гадиләштерелә. К.Насыйриның иҗатына багышланган педагогик киңәшмәләр, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә. Әлеге юнәлештә ата-аналар, әби-бабайлар белән дә эш алып барыла. 2017 елда коллектив «Балалар бакчасында Каюм Насыйри мирасы» фәнни-гамәли конференциясендә катнаша. Бакчада эшләүче педагоглар тарафыннан күпсанлы методик куллану малар эшләнә, алар республикада гына түгел, аннан читтә дә файдаланыла.

И.Х.Хәлиуллин.

ДҮРТЕНЧЕ́ ГИМНА́ЗИЯ, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми урта белем бирү муниципаль бюджет уку йорты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2011).

Казан шәһәренең Киров районында урнашкан. 1991 елда ачыла. 2024 елда 785 укучы белем ала, 38 педагог эшли.

Гимназия инновацияләр кулланучы, һөнәри профильне тәгаенләүче һәм гуманитар фәннәрдән татар теле

буенча тирәнтен белем бирүче оешма буларак, эшчәнлегендә татар халкының мәдәни мирасын, телен саклап калуга, яшь буында рухи һәм әхлакый сыйфатлар үстерүгә, сәләтле балалар тәрбияләүгә һәм аларга ярдәм итүгә юнәлеш тота. Анда сәләтле бала, халык педагогикасы чаралары аша



Дүртенче гимназия.

укучыларга экологик тәрбия бирү, төрле мәдәниятләр яссылыгында укыту һәм тәрбияләү проектлары гамәлгә ашырыла. Шагыйрь Габдулла Тукай, композитор Сара Садыйкова музейлары, Советлар Союзы Герое, танк гаскәрләре генерал-лейтенанты Б.В.Шульгин исемендәге музей комплексы эшли.

Әлеге уку йортында балаларның К.Насыйри исемендәге төбәкара укулары, халык гореф-гадәтләренә багышланган «Сөмбелә», «Нәүрүз», «Карга боткасы», «Каз өмәсе», «Сабан туе» чаралары, Сара Садыйкова исемендәге «Калфаклы сандугач» төбәкара фестивале уздырыла. «Гимназия тукталышы» газетасы чыгарыла. Сәләтле балалар өчен «Бәллүр каләм», «Яшь музыкант», «Яшь рәссам», «Яшь биюче» номинацияләрендә, музыка өлкәсендә Сара Садыйкова исемендәге һ.б. бүләкләр булдырылган.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк Татарстан халыклары милли мәдәниятләренең иң яхшы традицияләренә таянып милли мәгариф системасын камилләштерүдәге һәм үстерүдәге, милли мәгариф оешмалары өчен укыту-методика комплектлары, туган тел һәм әдәбиятны өйрәнү өчен дәреслекләр эшләүдәге казанышлары өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

Е

ЕГЕРМЕНЧЕ́ ГИМНА́ЗИЯ Абдулла Алиш исемендә, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми урта белем бирү муниципаль бюджет уку йорты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2020).

Казан шәһәренең Совет районында урнашкан. 2001 елда гимназия балалар бакчасы бинасында ачыла. Эшли башлаган елында уку йортында — 39, 2024 елда 729 укучы белем ала; 45 педагог эшли. 2012 елда гимназия «Россиянең әйдәп баручы мәктәпләре» милли реестрына кертелә. 2015 елда уңышлы рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия эшчәнлеге өчен Абдулла Алиш исеме бирелә.

Гимназия үз эшчәнлегендә татар халкының гореф-гадәтләре һәм традицияләренә, мәдәниятенә карата мәхәббәт, милли үзаң, шулай ук башка халыкларның гореф-гадәтләренә, традицияләренә, мәдәниятләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлеш тота. Укучылар татар, рус һәм инглиз телләрен генә түгел, кайбер фәннәрне дә чит телдә өйрәнәләр. 2013 елдан гимназия «ЮНЕСКО ассоциациясе мәктәпләре» халыкара проектында катнаша; «Мәктәп-музей проекты кысаларында укучыларның мәдәни белемнәрен формалаштыру» инновацияон проектын гамәлгә ашыру барышында 2013–2018 елларда «Милли мирас», Абдулла Алишка һәм Алиш исемендәге бүләк лауреатларына багышланган «Алиш варислары», Бөек Ватан сугышына, Советлар Союзы Герое М.П.Девятаевка багышланган «Мәңгелек хәтер», К.Насыйри яшәгән чорны чагылдырган «Иске Татар бистәсе» музейлары ачыла. Уку йорты — ТР Мәгарифне үстерү институты, Казан федераль университетының Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм өстәмә белем бирү үзәгенең тәҗрибә мәйданчыгы.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк милли мәгарифне үстерүдәге казанышлары өчен бирелә.

ЕНИКИ́ЕВА Алсу Рәшит кызы (05.03.1963, Мәскәү өлкәсе Жуковский шәһәре), музыкаль фольклор белгече, педагог, педагогика фәннәре кандидаты (2006), профессор (2018). ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (2014).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1984), Казан шәһәрендә Совет районы Пионерлар йортында, Абдулла Алиш исемендәге шәһәр Балалар иҗаты сараенда эшли; әлеге оешмаларда эшләгәндә татар балалар фольклор ансамблен (1991), «Ак калфак» татар балалар фольклор ансамблен (1994) оештыра. 2005 елдан — Казан мәдәният һәм сәнгать университетында (2015 елдан — Казан мәдәният институты): татар музыкасы кафедрасы укытучысы, 2007 елдан — кафедра мөдире, 2008 елдан — этносәнгать иҗаты һәм татар музыкаль фольклоры кафедрасы мөдире. 2008 елда

уку йортында аның тарафыннан «Жомга көн» татар фольклор ансамбле оештырыла. Ансамбль татар халкының төрле этнографик төркемнәре авыз иҗаты, музыкаль һәм йола фольклоры үрнәкләрен профессиональ дәрәҗәдә башкара, Бөтенроссия, халыкара конкурслар һәм фестивальләр лауреаты, Гран-При иясе.

А.Еникиева — «Халык сәнгать мәдәниятен өйрәнү, саклау һәм үстерү проблемалары» фәнни мәктәбе җитәкчесе. Идел буе халыкларының җыр, йола һәм уен фольклоры әсәрләрен өйрәнү, эшкәртү һәм актуальләштерү юнәлешендә актив фольклор экспедициясе эшчәнлеге алып бара (экспедиция материаллары буенча «Җомга көн» ансамбле тарафыннан традицион йолалар һәм бәйрәмнәр торгызыла, тамашалар сәхнәләштерелә, традицион йола-бәйрәм композицияләре һәм уеннары күрсәтелгән видеоальбомнар яздырыла). Казан мәдәният институтында ел саен уздырыла торган халыкара «Этномириада» традицион мәдәният һәм халык сәнгать иҗаты конкурс-фестивален, 2024 елдан гамәлгә кергән халыкара «Традицион мәдәниятнең һәм халык сәнгать иҗатының күпкырлы дөньясы» фәнни-гамәли конференциясен оештыру буенча аның тарафыннан зур эш башкарыла.

Фәнни эшчәнлеге уку-укыту–методик ярдәмлекләр һәм фольклор әсәрләре җыентыклары төзүгә карый. Хезмәтләрендә К.Насыйри әсәрләренә зур игътибар юнәлтелә; галимнең тәрбия, сәламәтлек, милли фольклор мәсьәләләрен тирәнтен яктыртуы күрсәтелә; мәгърифәтченең хезмәтләрендә татар халык авыз иҗатына мөнәсәбәтле халык җырларын өйрәнүнең мөһим урын биләве, аның җыр кыйммәтен эмоциональлектә һәм сәнгать көчендә, телдән тапшырылучы шигъри иҗатның эстетик кыйммәтен — кешенең иң самими кичерешләрен һәм тойгыларын чагылдыруда күрүе, фольклорны хаклы рәвештә халык мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүдә җитди чыганак буларак бәяләве икърар ителә. К.Насыйриның үз әсәрләрендә («Кырык бакча», «Китап әт-тәрбия», «Кабуснамә» һ.б.) аның тарафыннан «хикәят» дип аталган мәзәк жанрына даими һәм җитди игътибарының сатира һәм юмор ярдәмендә тормыштагы төрле тискәре күренешләрне фаш итү, шуның аша җәмгыятьтә әдәп-әхлак нормаларын нығыту, кешеләрдә, аеруча яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләү омтылышы белән бәйле булуы ассызыклана.



А.Р.Еникиева

Хезм.: Каюм Насыйри хезмәтләрендә сәламәтлек хасиятләре // Мәгариф. 2008. №9; Каюм Насыйри әсәрләрендә мәзәкләр // Актуальные проблемы современной фольклористики: материалы международной научно-практической конференции. Казань, 2009; Каюм Насыри о татарских народных песнях и баитах // Вестник Чувашского университета, 2010, №1; История возникновения и особенности территориального расположения татарских этнокультурных центров // Вестник Челябинского университета. 2011. №21; Этнопедагогический потенциал музыкального фольклора в системе народной художественной культуры: учебное пособие. М., Берлин, 2017.

И.Х.Хәлиуллин.

Ж

ҖАМАЛЕТДИ́НОВА Зәлфирә Исхак кызы (02.12.1961, Татарстанның Лаеш районы Хәерби авылы), педагог, педагогика фәннәре кандидаты (2015). ТРның атказанган укытучысы (2022). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2009).

Казан педагогия училищесын (1981), Казан педагогия институтын (1986) тәмамлый. 1981–1986 елларда Лаеш районы Сокуры сигезьеллык мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. 1986 елдан — Чаллы шәһәрендә: 129 нчы балалар бакчасында тәрбияче, 1990 елдан — Автозавод район советы башкарма комитетында, халык белән эшләү буенча оештыручы педагог, 1991 елдан — 129 нчы балалар бакчасында тәрбияче, 1992 елдан — 54 нче гимназиядә башлангыч сыйныф укытучысы.

2005 елдан — Казан шәһәре Совет районының 20 нче гимназиясендә башлангыч сыйныф укытучысы, 2007 елдан — мәктәп директоры (кара: *Егерменче гимназия*). 2011 елдан — Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм өстәмә белем бирү үзәгенең өлкән укытучысы, 2016 елдан ТР Мәгарифне үстерү институтының мәктәпкәчә тәрбия һәм башлангыч белем бирү кафедрасы доценты.

З.Җамалетдинова башлангыч мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру, татар мәктәпләрендә дәресләрне иҗади үсеш технологиясе нигезендә укыту, татар теле дәресләрен заманча технологияләргә нигезләнеп алып бару, «Дини мәдәният һәм дөньяви этика нигезләре» курсы эчтәлеген планлаштыру һәм уку-укытуның башка мәсьәләләрен хәл итүгә, күпмәдәниятле белем бирү даирәсендә кече яшьтәге мәктәп балаларының этносара толерантлыгын формалаштыруга күп көч куя. Ул шулай ук татар мәктәпләренең башлангыч сыйныфлары өчен уку-укыту–методик комплекслар, фәнни-методик мәкаләләр, шул исәптән «Мәктәп һәм югары уку йортының полимәдәни белем бирү даирәсендә укучыларның гражданлык үзенчәлеген формалаштыру», «Иҗади шәхес үсеше факторы буларак, укытуда системалы эшчәнлек алымнары», «Полимәдәни мохиттә кече яшьтәге мәктәп балаларының этносара толерантлыгын формалаштыруның психологик-педагогик үзенчәлекләре», «Интерактив әлифба дәреслеген белем бирү процессында куллануның үзенчәлеге һәм әһәмияте», «Баланың шәхесен үстерүдә туган телнең (татар теленең) роле» һ.б. хезмәтләр авторы.



З.И.Җамалетдинова

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» һәм «Россия Федерациянең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре» күкрәк билгеләре иясе.


Хезм.: Татар теле: дүртьеллык башлангыч татар мәктәбенең 4 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, 2004; Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, 2013; Татар теле: башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, 2014; Татар теле. 1 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. Казан, 2020.

Әд.: Галимуллина Г.Х., Насибуллина А.Б. Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр. Казан, 2019.

Ф.С.Гыйниятуллина.

«ҖӘВАҺИ́Р ӘЛ-ХИКӘЯ́Т» («Җәваһир әл-хикәят вә л-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсилә» — «Хикәятләрнең, сорауларның, мәзәкләрнең, риваятьләрнең, мәсәлләрнең җүһәрләре»), хикәя. Борынгы гарәп дин эшлеклесе имам әс-Соютыйның (1445–1505) «Китаб әнис әл-җәлис» («Мәҗлестәшләрнең дусты») хезмәтеннән Каюм Насыйри тарафыннан тәрҗемә ителгән һәм 1884 елда Казан университеты басмаханәсендә бастырылган.

Китапта мөселман белергә тиешле азан, дога, мәрхүмнәр, диңгез хайваннары, галимнәр, Адәм, Муса, Сөләйман, Йосыф, Гайсә, Мөхәммәд пәйгамбәрләр, Ибраһим пәйгамбәрнең улы Исмәгыйльне Аллаһы ризалыгы өчен корбанга китерү, Дауд пәйгамбәр һәм аның туксан тугыз хатыны, Мөхәммәд пәйгамбәрнең дүрт сәхабәсе: Әбубәкер, Гомәр, Госман, Гали; имам Газзәли, яшәү һәм үлем, Гыйрат шәехе, Искәндәр һәм төрле дарулар җыючы вәзире, Әбу Хәнифә һәм аның сыйфатлары, өч изге һ.б. турында мәгълүмат китерелә. Илле тәкъва мөселман тормышы хакында хикәя урнаштырылган.



К.Насыйри. «Җәваһир әл-хикәят». Казан, 1887.

Башка басмалары Казан университеты басмаханәсендә 1887, 1889, 1894, 1898, 1900, 1905 елларда (соңгы икесе Исмәгыйль Шәмсетдинов иганәсендә) нәшер ителә.

Чыг.: Насыйри К. Җәваһир әл-хикәят. Казан, 1884.

Әд.: Катанов Н. «Джауагиру'ль-хикаят уа'ль-асиле уа лятаифу'р-риуаять уа'ль-амсиле» (драгоценности рассказов и вопросы, остроумия, предания и притчи). Казань, 1898. Типогр. ун-та. 136 стр. // Деятель. 1898. № 8–9.

Р.Ф.Исламов.

ҖӘДИТЧЕЛЕ́К (гарәп теленнән جديد — яңа), мәгърифәтче-ислахчылык иҗтимагый-сәяси яңарыш хәрәкәте. 19 йөзнең 2 нче яртысы – 20 йөз башында Идел буе, Кырым, Кавказ аръя-

гы, Урта Азия мөселман халыклары арасында таралыш ала.

Җәдитчелекнең төп принциплары үсешен һәм формалашуын кырым-татар мәгърифәтчесе һәм журналисты Исмәгыйль Гаспринскийның мәдәни-агарту эшчәнлеге белән бәйлиләр. Яңарыш хәрәкәте асылындагы сәяси-идеологик сыйфатларны Морад мулла һәм Батырша, Габденнасыйр Курсави эшчәнлекләре белән раслап, әлеге күренешне мөселман ислахчылыгы белән тәңгәлләштерәләр. Җәдитчелек татар җәмәгатьчелегенең иҗтимагый-сәяси тормышында мәгърифәтчелек, мөселман (ислам) ислахчылыгы һәм иҗтимагый-сәяси юнәлешләрдә үсеш ала. Бу хәрәкәт, коллектив аң формасы буларак, үз чиратында, мәгариф системасын камилләштерүне, мөселман ислахчылыгын активлаштыруны, икътисади мөнәсәбәтләрне үстерүне һәм иҗтимагый-сәяси көчләрне берләштерүне таләп итә.

Россиядә социаль-сәяси вазгыять хөкем сөргән шартларда татар җәдитчеләре мөселман бергәлегенең тотрыклы нигезләрен саклап калуны, ислахчылык исламга элегрәк хас булмаган мәдәният һәм сәяси тормышның кайбер кагыйдәләрен рухи байлыгы итеп сайлап алуны һәм үз милли көнкүрешендә җайлаштыруны, мөселман өммәтенең интеллектуаль һәм сәяси көчләрен торгызу зарурлыгын яклап чыгалар. Моннан тыш, сәяси институтларны яңадан торгызу мөмкин булмаган шартларда, татарларда җәмгыятьне берләштерүче социаль-мәдәни интеграция факторы сыйфатында җәмәгать мәдрәсә-мәктәпләре, хәйрия һәм мәдәният оешмалары төзү, китапханәләр ачу, ана телендә газета-журналлар, татар халкының диненә, тарихына һәм мәдәниятенә караган хезмәтләр бастыру алгы планга чыга.

Каюм Насыйри әлеге мәдәни-мәгърифәт һәм иҗтимагый-сәяси агым тарафдары саналмаса да, аның эшчәнлегендә һәм хезмәтләрендә татар халкының мәгариф системасын (уку-укыту әсбапларын, укыту һәм тәрбия бирү ысулларын камилләштерү) һәм белем дәрәҗәсен актив үстерү төп максат итеп куела. Татарларның тормышын һәрьяклап колачлаган иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә галим мөселман мәгарифен үзгәртеп коруның төп юнәлешләрен билгели. Мәгариф алгарышы, аның фикеренчә, татар халкының рухи яңарышы һәм интеллектуаль потенциалы үсешенең бердәнбер мөмкин формасы була. Моннан тыш ул капиталистик мөнәсәбәтләр формалашып килгән шартларда татар җәмгыятенең сәләтле кадрларга мохтаҗлык кичерүен аңлый. Әлеге буржуаз чынбарлыкның алдагы перспектив юнәлешләрен күзаллап, К.Насыйри үзенең фәнни һәм фәнни-популярлаштыру эшчәнлегендә уку-укыту әсбапларын Европа (шул исәптән Россия) һәм Көнчыгыш илләренең алдынгы үрнәкләре рәвешендә яңача үзгәртеп эшләүгә, татар балаларын ана теле белән бергә рус телендә укытуга, татар халкының тарихы, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән бергә руслар һәм башка халыкларныкын да өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирә. Татар халкының яшәп килгән мәгариф системасын заманча яңарту максатыннан чыгып, К.Насыйри тел, әдәбият, халык авыз иҗаты, арифметика, геометрия, география, этнография, астрономия, физика, химия, ботаника, агрономия, медицина, анатомия, гигиена, әхлак, тәрбия һәм башкалар буенча хезмәтләр һәм дәреслекләр яза, тәрҗемәләр ясый. Аның күпчелек уку әсбаплары, алдынгы дидактик принципларны һәм уку-укыту ысулларын исәпкә алып, яңа татар телендә язылган.

19 йөзнең 2 нче яртысында К.Насыйри беренчеләрдән булып татарлар арасында рус телен таратуга зур әһәмият бирә. Галим-педагог татар халкының мәгърифәтен үстерүдә *рус-татар мәктәпләренең* кирәклегенә һәм мөһимлегенә төшенә. Ул рус-татар мәктәпләре өчен дәреслекләр төзи, аларны оештыру буенча татар халкы арасында аңлату эшләре алып бара, Россиядәге милли мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгын һәм татарларга моны һәрдаим истә тоту зарурлыгын яхшы аңлый, Россиядә яшәгән татарлар өчен аның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү, шулай ук рус телен үзләштерү — империя кысаларында яшәү өчен кирәк булган мөһим шарт, әмма бу процесс ана телен, үз туган телеңне югалту хисабына барырга тиеш түгел дип саный. Килеп туган халәттән дөрес чыгу юлын милләттәшләренә ярдәм йөзеннән «Кавагыйде кыйраәте рус» («Русча уку кагыйдәләре», 1889), «Нәмүнә, яки әнмүзәҗ» («Гарәп теле үрнәгендә төзелгән рус теле грамматикасы», 1891), «Лөгате рус китабы» («Рус-татар сүзлеге», 1892), «Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь» («Кыскача рус тарихы», 1890) дәреслекләрен язуда күрә.

Ислам дине тарафдары буларак, К.Насыйри, 19 йөзнең соңгы чирегендә иҗтимагый яңарыш нигезен төзү, аны тагын да камилләштерү өчен яңа мөмкинлекләрдән чыгып, исламның татар варианты асылын үстерүгә зур әһәмият бирә. Мөселман йолалары, әхлагы һәм ислам тәгълиматы таратуга багышланган әсәрләр дә калдыра. Шул ук вакытта ул Аллаһы Тәгалә һәм фани дөнья мөнәсәбәтләрен икелек (деизм) фәлсәфәсе карашыннан торып аңлата. Аныңча, җиһандагы тәртип, табигать күренешләренең агышы Аллаһ тарафыннан билгеләнә, ләкин ул әлеге агыш-күренешләргә туры дан-туры катнашмый. «Бу дөнья, — дип яза ул, — сәбәпләр дөньясы. Без мохтаҗ булган бар нәрсә билгеле бер сәбәпкә бәйле. Әлеге сәбәпләрне уй-фикер йөртеп, акыл белән эзләнеп кенә аңлап-белеп була. Күренешләрнең сәбәбен белергә һәм шуларга таянып хәрәкәт итәргә кирәк». Ул фәннең һәм кеше акылының дөньяны танып белүдәге һәм күренешләрнең сәбәпләрен ачыклаудагы урынына аеруча зур басым ясый. Бу — аның тормышны, табигатьне һәм кешенең тормыштагы урынын аңлаудагы иң алдынгы карашларының берседер.

К.Насыйри, татар халкының белемен һәм үзаңын үстерүне күздә тотып, 30 ел дәвамында иҗат иткән *календарьларында* фәннең һәм көнкүрешнең төрле тармакларына караган берничә йөз фәнни-популяр мәкалә яза. Татар вакытлы матбугаты вазифаларын башкарган еллык календарьлары укучыларны табигать белеме, тарих, география, әдәбият, халык авыз иҗаты, тел гыйлеме һәм башка фән тармакларына караган мәкаләләре һәм язмалары белән дә таныштырып бара. Аларда басылган материаллар татар милләтенең яшәү һәм хезмәт шартларын яктырта, биредә шул чорда чыккан китапларга һәм хезмәтләргә бәяләмәләр, әхлак һәм тәрбия, игенчелек һәм сәнәгать буенча мәгълүматлар, публицистика үрнәкләре һәм башка материаллар урнаштырыла.

Әд.: Шәймәрданов Р.Х. Габделкаюм Насыйри иҗаты һәм эшчәнлегенең бүгенге көн әһәмияте // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию со дня рождения Каюма Насыри. Казань, 2015; Абдуллин Я.Г. Джадидизм среди татар: возникновение, развитие и историческое место. Казань, 1998; Исха-

ков Д.М. Феномен татарского джадидизма: введение к социокультурному осмыслению. Казань, 1997; Мухаметшин Р.М. Татары и ислам в XX веке. Казань, 2003.

Р.В.Шәйдуллин.

ҖӘЛӘЙ (Җәләлетдинов) Латыйф Җәләлетдин улы (17.11.1893, Самара губернасының Мәләкәс өязе Татар Урайкиносы (Иске Кызылсу) авылы – 01.08.1966, Казан), тел галиме, педагог, филология фәннәре докторы (1954), профессор (1958).

Мәләкәс мәдрәсәсендә белем ала (1911). 1921 елдан Самара шәһәрендә: балалар йорты мөдире, педагогия техникумында укыта. 1928–1929 елларда — халык мәгарифе бүлеге инспекторы. 1929–1932 елларда Кузнецк (Урта Идел буе өлкәсе, хәзер Пенза өлкәсе) һәм Мәләкәс шәһәрләре партия мәктәпләрендә эшли. 1933 елдан Казанда: 1935 елдан — Казан педагогия институтында. 1944 елдан — Казан университетында, бер үк вакытта, 1962 елга кадәр — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1951–1953, 1956, 1961 елларда — тел белеме секторы мөдире).

Хезмәтләре татар теле тарихы, орфоэпиясе, стилистикасы, диалектологиясен, тарихи тел белемен, татар халкының борынгы әдәби ядкәрләрен өйрәнүгә карый. Каюм Насыйри, Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Афзал Шамов һәм башка татар язучыларының һәм галимнәренең иҗаты, эшчәнлеге турында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре; мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы. К.Насыйригa багышлаган хезмәтләрендә ул аның милли мәгърифәтчеләребез арасында тоткан урынын күрсәтә, киңкырлы фәнни, аеруча татар теле һәм әдәбиятына караган эшчәнлеген яктырта. Галимнең К.Насыйриның тууына 120 ел тулу уңаеннан язылган һәм «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргән «Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри» мәкаләсендә һәм мәгърифәтченең шул ук елда нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр» басмасындагы «Каюм Насыйри (1825–1902)» язмасында Насыйри эшчәнлеге борынгыдан ук яшәп килгән һәм 19 йөзнең 2 нче яртысында инде яңа принципларга нигезләнгән мәгърифәтчелек хәрәкәтенең синтезы буларак сыйфатлана, аның шәхесе — Михаил Ломоносов, татар тарихында зур яңалык булган фундаменталь «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» хезмәте (1884) рус әдәбиятындагы жанры ягыннан шундыйрак юнәлештә (әдәби китап һәм халык сөйләме синтезы буларак) язылган «Домострой» (16 йөз уртасына караган протопоп Сильвестр варианты) белән чагыштырыла; К.Насыйриның беренче тапкыр милли җәмәгатьчелеккә «бүтән халыклар телләре өстендә эшлиләр, безгә дә телебез өстендә эшләргә кирәк» дигән мөрәҗәгате, «Әнмүзәж», «Кавагыйде китабәт», «Ләһҗәи татари» һәм башка хезмәтләре, «Татарча-русча сүзлек»ләре, чагыштырма грамматика басмалары белән татар теле үсешенә керткән өлеше, телнең грамматик төзелеше, орфография, орфоэпия кануннарына карата шактый зур принципиаль мәсьәләләр күтәрүе һәм аларны хәл итүе, төрле фән тармаклары буенча дәреслекләр язуы югары бәяләнә; ул ««урам теле» хисапланып, кимсетелеп йөртелгән татар хезмәт ияләре теленең яшерен көчен уятучы һәм беренче баш-



Л.Ж.Җәләй

лап аны әдәби тел югарылыгына күтәрү өстендә эшләүче, фәнни һәм практик әйләнешкә кертүче», энциклопедист, үз халкын хорафат-мифлардан арындыручы, киң демократиянең җанлы сөйләмендәге сүз байлыгына корылган яңа сыйфатлы әдәби телгә нигез салучы, «аны фәнни эшкәртүнең төп юнәлешләрен сызып бирүче», «татар тел белеменең атасы» буларак тәкъдим ителә.

Хезм.: Каюм Насыйри (1825–1902) // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри // Совет әдәбияты. 1945. № 2; Татар диалектологиясе. Казан, 1947; Татар теленең орфоэпик нигезләре. Казан, 1953; Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. Казан, 1954; Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. Казан, 1957 (автордаш).

Әд.: Сабиров К. Профессор Л.Заляй и татарское языкознание // Вопросы татарского языкознания. Казань, 1965. Кн. 2; Якупова Г. Латыф Залялетдинович Залялетдинов // Советская тюркология. 1974. № 6.

И.Х.Хәлиуллин.

ҖӘЛӘЛИ́ЕВ Шамил Шәйхи улы (23.05.1930, Татарстанның Әтнә районы Югары Шашы авылы), тарихчы, педагог, педагогика фәннәре кандидаты (1974). РСФСРның һәм СССРның Халык мәгарифе отличнигы (1962, 1980), ТРның атказанган укытучысы (2003). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2005).

Казан педагогия институтын тәмамлый (1961).1953 елдан Олы Әтнә урта мәктәбендә тарих һәм җәмгыять белеме укыта, 1980 елдан милли мәктәпләрдә, фәнни-тикшеренү институтында эшли. 1996–2006 елларда — ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр.



Ш.Ш.Җәләлиев

Хезмәтләре татар халык педагогикасы, милли мәгариф тарихы мәсьәләләренә карый. Каюм Насыйриның педагогика, тәрбия өлкәсендәге фәнни-мәгърифәтчелек эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр авторы. «Мәгариф» журналында дөнья күргән «К.Насыйри иҗатында татар халык тәрбиясе» мәкаләсендә, «Милли тәрбия нигезләре: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре, педагогия колледжлары, училищелары өчен уку ярдәмлеге»нең 5 нче бүлегендә («Каюм Насыйри иҗатында татар халык тәрбия тәҗрибәсе», «Тел һәм холык турында халык гыйлеменең Каюм Насыйри иҗатында чагылышы» параграфларында) галимнең милли халык педагогикасын шәхси тормыш тәҗрибәсе, төрле чыганаклар, шул исәптән үзе йөреп туплаган фольклор әсәрләре, халык белән якыннан аралашуы аркылы өйрәнүе, педагогика һәм тәрбия мәсьәләләрен хәл итүне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре, әлеге мәсьәләләрнең «Кырык бакча», «Китап әт-тәрбия», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» әсәрләрендә кешенең тормыш-яшәеш проблемалары аша чагылышы, аның төп педагогик принцибының халыкчанлык һәм гуманлылыктан гыйбарәт булуы бәян ителә.

Медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар халык педагогикасы. Казан, 1997 (2 нче басма — 2003); К.Насыйри иҗатында татар халык тәрбиясе // Мәгариф. 2001. № 6; Милли тәрбия нигезләре: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре, педагогия колледжлары, училищелары өчен уку ярдәмлеге. Казан, 2003.

И.Х.Хәлиуллин.

ҖЫР, халык авыз иҗатында лирик жанрларның иң киң таралганы; сүз-текст белән көйнең үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкарыла торган шигъри-музыкаль әсәр. Җырның төп функциясе — халыкның һәм шәхеснең рухи дөньясын, фикер һәм хис-кичерешләрен чагылдыру.

Татар халык җырларының тамырлары ерак гасырларга барып тоташа. Аларның шигъри-музыкаль традициясе жанрлар системасыннан гыйбәрәт; йола (туй, мәҗлес, кунак хөрмәтләү), бәйрәм (халык бәйрәмнәре, яшьләр уеннары), хезмәткә багышланган, эпик, лирик, музыка уен коралларына башкарыла торган җырлар халык тормышының төрле якларын чагылдыралар. Татар халык көйләре пентатоника — биш баскычтан торган һәм үзендә ярымтоннар булмаган авазлар рәтенә нигезләнә, аларда гомуммөселман традицияләренең милли үзенчәлекле жанрларын аерым моң белән башкару күзәтелә.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, өйрәнүгә һәм бастырып чыгаруга аеруча зур әһәмият бирелә. Ул татар халык *бәетләрен*, *әкиятләрен*, *мәкальләрен*, *сынамышлар*, *табышмакларын*, *риваятьләрен*, *ырымнарын*, *ышануларын* барлау белән бергә Казанда, Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендә яшәгән татарлар арасында сакланган җырларны туплауны мөһим бурычы итеп саный. Аның «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)» язмасы басылып чыга, анда татар халык авыз иҗаты әсәрләренең 417 үрнәге, шул исәптән 145 җыр урнаштырыла. «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» дигән әсәрендә 117 җыр китерелә.

Җырларны махсус өйрәнүнең башлангычы К.Насыйри исеме белән бәйле. Аның эшчәнлегендә татар халык җырларын өйрәнү аерым урын алып тора. Ул җырның эстетик кыйммәтен инсанның иң саф һәм нечкә хисләрен гәүдәләндерүдә күрә. Үз чоры тикшеренүчеләреннән аермалы буларак, җырларга тарихи-этнографик чыганак итеп кенә карамый, аларның эмоциональ фонына һәм сәнгать көченә дә аерым игътибар бирә. К.Насыйриның «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре» хезмәтенә кереш сүзендә


410 л. к. насыйри.

صاغوب مراڵان سوڵڵر

Грустныя пѣсни.

1. صاغوب‌ڵاغ‌مڭاجيم‌صاڵماى‌من ✻ صاپرماى‌ساى‌تورمون ديڭلكين
صاغلمان‌ياقد‌ديوى‌سڵامك ✻ صارغايروب‌ڵو‌لسون‌ديڭلكين

Ты не кладень кору сосновую, вѣрностію, для того, чтобъ онъ не плылъ. Когда я грущу, не понимаешь моей печали, вѣрностію, для того, чтобъ я умеръ въ печали.

2. بيكروب‌توشدم‌باغچه‌غه ✻ تارماڭ چى آلماغه
تارماڭ چى ماڵ چى ✻ كوڭڵ‌يكان‌مانماى‌ماڭا‌يقروب

Я запрягалъ въ сани, чтобъ ѣхать зимнюю тропочку. Тонкая тропочка—палочка. Не успѣла ли, душечка, опять мнѣ?

3. ترم‌تورى‌صاڵيوغاچ ✻ اوچماسوب‌كتار‌ساپراغاچ
مراڵ‌توكڵ‌ڵاڵ‌من ✻ ايسلاشكا‌توشوب‌ساقماغاچ

Подъ окномъ у меня сосенка: когда онъ зашелъ, я прощаюсь. Не только вышелъ, но и запалился, когда, вспомнилъ, отрутился.

4. قارا‌اورمان‌تك‌آرتسه ✻ قارلماچ‌بولور‌قاغلغان
اوڵڵى‌توشه‌نوت‌ايسكه ✻ من‌بولورمن‌مني‌صاغلغان

За чернымъ лѣсомъ листочекъ—снѣжинка прилѣпился. Когда будешь плакать, вспомни, что я скучалъ по тебѣ.

5. باغچه‌ده‌كڵسه‌آلمالى ✻ آلمالى‌توكڵ‌ڵالمالى
سنده‌غيرى‌بوى‌سيركام ✻ اينان‌تڵاسمه‌ده‌ڵله

Въ саду розы съ цвѣтами, не съ цвѣтами, а съ ягодами. Кромѣ тебя нѣтъ у меня любовей, поберегъ моихъ слезъ ради Бога.

К.Насыйри. «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндәге мәкаләдән бер бит. 1896.

Н.Ф.*Катанов*: «Бу җырларда татар халкы күңеленең шатлыклы һәм моңсу халәтенең образлы һәм җиңел тасвирлануын күрергә мөмкин», — дип яза. Җырларга бәя биреп, мәгърифәтче аларны халык мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүдә җитди чыганак дип саный.

К.Насыйри җыр текстларын «шигырьләр» термины белән атый, аларның ритмик, моңлы булуына сокланна. Аның тикшеренүләрендә мәхәббәт турында җырлар мөһим урын алып тора. Алар бигрәк тә «*Кырык*

бакча», «*Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият*» әсәрләрендә мулдан китерелә. Галим җырларны 7 төргә — моңсу җырлар (13 җыр), мактау җырлары (12), кавышу теләгән белдергән җырлар (26), кайгылы җырлар (14), үкенүле җырлар (15), аерылышу җырлары (36), мәхәббәт җырлары (29) төрләренә бүлә.

Алар арасында: «Мәхбүбләрне мәдех бәянында»: Укый торган намазлыгым / Чүпләмәгән җире калмаган; / Күргән саен карыймын, / Һич килмәгән җирең калмаган.; «Һиҗран вә фирак шигырьләре»: Җырласаң, егет, ачы җырла, / Йокыдагы кызлар уйгансын; / Дәртле бардыр. Дәртсез бардыр, / Дәртлеләрнең күңеле юансын. «Иштиякъ, васләт»: Көмеш йөзек бармакта, / Кашлары аның балдакта; / Шул җаный белән күрешеп / Сөйләшербез микән аулакта?; «Интизар хәбәр вә сагынмалык»: Сандугачыңа җим сипмисең, / Сайрамый торсын, дисеңме; / Сагынган чакта юк сәламең, / Саргаеп үлсен, дисеңме.; «Һиҗран вә җәүр, мәгъшуктан шикаять вә үпкә»: Кашларың — кара каләмдер, / Бу шигырьләрем — сиңа сәламдер; / Бу сәламемне алмасаң, / Сөешүләребез безнең әрәмдер.; «Фирах вә өмид васләт»: Без элгәре бик дус идек, / Инде булдык, җаный, әлфирак; / Бу фирактан дәһи кавышмасак, / Үлгәнемез безнең яхшырак.

Халык җырларының матурлыгына һәм ихласлыгына игътибар юнәлтеп, К.Насыйри кешенең мәхәббәт хисләрен кадерләргә һәм хөрмәт итәргә, шатлыкларын һәм кайгыларын, шәхси бәхеткә омтылышын аңларга өнди. Аның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»ында җырларны пропагандалауга зур урын бирелә. Галим: «Әгәр кеше хәсрәт кичерә икән, яхшы җыр тыңласын. Берәрсенең күңеле авырта икән, җыр аңа тынычланырга ярдәм итәчәк. Матур тавыш — рухи азык, ул фикерләрне чистарта, акыл эшчәнлеген арттыра, игелекне арттыра, куркакны каһарман итә, саранны юмарт итә», — дип нәтиҗә ясый. Матбугатка чыгару өчен җырлар сайлаганда ул аларның композицион үзенчәлегенә дә игътибар итә. «Безнең телебезнең җырлары һәрвакыт ике юлдан тора, һәм күпчелек очракта төп фикер соңгы юлда чагыла. Телебезнең тагын бер үзенчәлеге шунда ки, бер үк җырны ун-унбиш көйгә җырлап була», — дип яза. Галим җырларның чагыштыруларга, метафоралар һәм эпитетларга бай булуын билгеләп үтә.

Әд.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2005. 3 т.; Язучы мөтәрҗим. Казан татарларының тарихи җырлары // Шура. 1911. № 17; Еникеева А.Р. Каюм Насыри о татарских народных песнях и баитах // Вестник Чувашского университета, 2010. №1; Катанов Н.Ф. Исторические песни казанских татар // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1899. Т.15, вып.3; Насыри К. Советы матерям, воспитывающих детей. Казань, 1992; Насыров К. Образцы народной литературы казанских татар // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1896. Т.XXIII, вып. 5.

Э.М.Галимова.

З

ЗАКИ́РОВА Кафия Вәли кызы (30.03.1951, Татарстанның Арча районы Түбән Курса авылы), педагог, РФнең Халык мәгарифе отличнигы (1993), РФнең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре (2009), ТРның атказанган укытучысы (2016). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2017).

Арча педагогия училищесын (1969), Казан педагогия институтын (1978) тәмамлый. 1969 елдан Арча районы Кышлау авылында балалар бакчасы мөдире. 1973–2018 елларда Казанның 233 һәм 415 нче балалар бакчаларында тәрбияче, методист булып эшли. Бер үк вакытта, 1996–2005 елларда ТР Мәгариф министрлыгының фәнни-методик үзәгендә дәреслекләр эшләү секторы мөдире, 1995–2017 елларда Казан шәһәре Совет районында «Мирас» иҗади эшләүче педагоглар семинары җитәкчесе.

Фәнни-методик хезмәтләре мәктәпкәчә тәрбия, әдәп-әхлак мәсьәләләренә һәм татар балаларын милли рухта тәрбияләүгә карый. Тәрбия-белем бирү татар телендә алып барыла торган балалар бакчалары өчен 30 дан артык программа, методик кулланмалар төзи. Әлеге әсбапларны Башкортстан, Чуаш Республикаларындагы, Оренбург, Пермь һәм башка өлкәләрдәге балалар бакчалары тәрбиячеләре дә куллана. Шулай ук «Ислам диненең рухи-әхлакый кыйммәтләре белән таныштыру программасы» (2006), «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү» программасының милли-төбәк юнәлеше» (2009) һәм башка уку әсбаплары авторы. Алар халык педагогикасы, шул исәптән татар мәгърифәтчеләре Каюм Насыйри һәм Риза Фәхретдин хезмәтләренә нигезләнеп эшләнә. Тәрбия эшендә К.Насыйри иҗатын файдалануның заманча алымнарын тәкъдим итә. Галимнең «Китаб-әт-тәрбия» хезмәте нигезендә балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе буенча программа, методик кулланмалар төзи.



К.В.Закирова

Медаль, ТР Фән һәм мәгариф министрлыгының «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Хезм.: Әткәм-әнкәмнең теле. Казан, 1997; Көч һәм рух тамырлары. Казан, 1998; Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе. Казан, 1999; Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. Казан, 2000; Уйный-уйный үсәбез. Казан, 2005; Балачак — уйнап-көлеп үсәр чак. Казан, 2012 (автордаш); «Әй уйныйбыз, уйныйбыз...». Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар. Казан, 2013 (автордаш); Ба-

лалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе. Казан, 2013.

Ф.Г.Камальтдинова.

ЗА́ЛЕМАН Карл Германович (Генрихович) (09.01.1850, Россиянең Ревель (Таллин) шәһәре – 13.12.1916, Петроград), Иран мәдәнияте һәм тарихы белгече, Петербург Фәннәр академиясе академигы (1895), Гисен университетының шәрәфле профессоры (1902), Венгрия Фәннәр академиясең мөхбир әгъзасы (1904), Император Рус археология җәмгыяте (1882), Рус Урта һәм Көнчыгыш Азияне өйрәнү комитеты (1903), Король Азия җәмгыяте (1908) шәрәфле әгъзасы.

Петербург университетының Шәрекъ факультетын тәмамлый (1871). 1875 елда «Хакани дүртьюллыклары» темасына диссертация яклый һәм аңа фарсы әдәбияты магистры дәрәҗәсе бирелә, приват-доцент вазифасында раслана; 1876–1916 елларда Шәрекъ факультетында зенда (авеста) һәм пәһләви әдәбиятлары буенча лекцияләр курсы укый. Бер үк вакытта, 1875 елдан университет китапханәчесе ярдәмчесе, 1879 елдан китапханәчесе, 1890 елдан Петербург Фәннәр академиясенең Азия музее һәм Император Фәннәр академиясе китапханәсенең 2 нче бүлеге директоры.

Директор вазифасында музей китапханәсен һәм кулъязмалар тупланмасын үстерү-баету белән шөгыльләнә, даими рәвештә өстәлеп барган кулъязмаларның тасвирламаларын бастыра һәм әдәбият каталогын төзи, бер үк вакытта гарәп, фарсы, төрки, шул исәптән Каюм Насыйри кулъязмаларын каталоглаштыра. Аның тырышлыгы белән Азия музеенда гаҗәеп бай китапханә туплана.

1880 елда Казанга фәнни сәфәре вакытында К.Насыйри белән актив



К.Г.Залеман

аралаша, аның ярдәмендә татар телен үзләштерү дәрәҗәсен камилләштерә. Мәгълүм булганча, 1880 елларда Британия Библия җәмгыяте тәкъдиме белән Матфей (Казан, 1882; 2 нче басма — 1890) һәм Марк (Казан, 1886) Инҗилләрен татар теленә тәрҗемә итә. Әлеге эшчәнлеге вакытында татар теле буенча аның киңәшчеләренең берсе, текстларының мөхәррире К.Насыйри булуы ихтимал.

Хезмәтләре фарсы филологиясенә, урта Иран пәһләви һәм согуд телләрен, шулай ук осетин, Памир (шугнан һәм ягноб) телләрен өйрәнүгә багышлана. Урта фарсы манихеячел ядкәрләрне тикшерә, шуның нәтиҗәсендә сасанилар чоры урта фарсы теленең фонетик системасы ачыклана. 20 йөз башында Шөнҗан территориясендә табылган текстларны шәрехләп нәшер итә («Манихеячел этюдлар» («Манихейские этюды») сериясе, 1908).

3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче дәрәҗә Изге Станислав, 1 нче дәрәҗә Изге Анна, Игелекле Бохара орденнары белән бүләкләнә.

Хезм.: Краткая грамматика новоперсидского языка, с приложением метрики и библиографии. СПб., 1890 (автордаш В.А. Жуковский); Среднеперсидский язык. СПб., 1902; Мусульманские рукописи, вновь поступившие в Азиатский музей в 1909–1910 гг. // Известия Академии наук. Серия VI. 1911. Т. 5, № 4; Persische Zaleman Карл Германович 165 Grammatik mit Litteratur, Chrestomathie und Glossar. Leipzig, 1889 (автордаш В.А. Жуковский), Scham-si-Fachrii lexicon Persicum. Казань, 1887.

Әд.: Периханян А.Г. Карл Германович Залеман // Очерки по истории русского востоковедения. М, 1959. Т. IV.

Р.В.Шәйдуллин.

«ЗАПИ́СКИ ИМПЕРА́ТОРСКОГО РУ́ССКОГО ГЕОГРАФИ́ЧЕСКОГО О́БЩЕСТВА», кара: *«Император Рус география җәмгыяте язмалары»*.

ЗАРИ́ПОВ Эрот Якуб улы (20.07.1938, Свердловск өлкәсенең Уинск районы Иштирәк авылы – 12.05.2009, Казан), график, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977).

Башкортстаннын Яңавыл районы Ямады авылында үсә. Львов полиграфия институтын тәмамлый (1965).

Рәсем сәнгатендә беренче адымнарын Пермь шәһәренең мәдәният сараенда В.Ф.Кузин җитәкчелегендәге рәсем сәнгате студиясендә, соңрак Хабаровск шәһәре рәссамнар йортының сурәтләү студиясендә ясый. Аларда ул һәвәскәр рәссамнар күргәзмәләрендә катнашып килә.1966 елдан — Татарстан китап нәшриятында: бизәлеш мөхәррире (1966–1969), баш рәссам (1978–1981), штаттан тыш рәссам (1969–1972; 1981–1990). 1975–1978 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре. 1990 елдан — ТР Милли китапханәсендә рәссам.

Э.Зарипов пейзаж, анималистик мотивлар сайлаганда үзенең гажәеп бай фантазиясен күрсәтә. Үз колоритында ул җыйнак, кырыс, төгәл, хәтта бераз корырак та. Шулай да рәссам декоратив штрихларга зур әһәмият бирә. Күкне, җирне, предметларны тоник төсләрдә түгел, ә ниндидер якты, ачык штрихлар аша тасвирлый. Ул китап һәм станлы графика өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе.



Э.Я.Зарипов

15 кә якын китапны, шул исәптән Мәрзия Фәйзуллинаның «Шаян ай» (1966), Илдар Юзеевның «Исәнме, туган җир!» (1970), «Пони малае нәни Җирәнкәй» (1971), Разил Вәлиевнең «Хыялый песи малае» (1976), Әхмәт Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» (1968), «Габдулла Тукай. Альбом» (1978) китапларын бизи һәм аларга рәсемнәр ясый; 100 гә якын китап тышлыгы авторы.Китап бизәү өлкәсендәге уңышлары өчен Бөтенроссия күләмендә оештырылган китап бизәү сәнгате конкурсларында дипломнар белән бүләкләнә. Станлы графика өлкәсендә линогравюра, монотипия, офорт, акварель, карандаш техникасы белән тематик һәм пейзаж жанрларында эшли: «Туган авыл» (1966–1970), «Казанның архитектура һәйкәлләре» (1979–1980), «Нефтьчеләр турында» (1980) линогравюралар сериясе; «Болгарлар» (1978), «Борынгы Львов» (1963) төсле монотипияләр сериясе һ.б.

1990 елдан иҗатында төп урынны портрет жанры алып тора, аларда — замандашлары образлары, татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре; шагыйрьләр, мәгърифәтчеләр, галимнәр, язучылар, композиторлар, рәссамнар. Бу жанрдагы әсәрләре «Татар мәгърифәтчеләре» линогравюралар сериясеннән башлана һәм төсле катнаш техникада башкарылган әсәрләрендә дәвам иттерелә (барлыгы 200 табактан артык). Портретлар арасында — «Шиһабетдин Мәрҗани», «Каюм Насыйри», «Габдулла Тукай», «Габденнасыйр Курсави», «Дәрдемәнд», «Һади Такташ», «Бакый Урманче». 1996 елда башланган «Багышлау» биография-

ләр сериясе Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Гариф Ахунов, Роберт Миңнуллин һәм башка шагыйрь һәм язучыларга багышлана, һәркайсының туган җирләрендә күрсәтелә.



Э.Я.Зарипов. «Каюм Насыйри». Линогравюра. 1984.

Рәссам күп кенә шәхесләрне фоторәсемнәре аша сурәтләсә, Каюм Насыйри портретын иҗат итүдә аңа тарихи чыганаклар, замандашлары сөйләп калдырган истәлекләр ярдәмгә килә. Кече Шырдан авылы халкы сорамы буенча К.Насыйриның тагын бер портретын яза. Ул әдип-галимнең туган авылы *Кече Шырдан* музее китапханәсендә саклана. Рәссам мәгърифәтчене шырданлыларга хас булганча кыю, зирәк фикерле, тырыш шәхес буларак тасвирлый.

1963 елдан республика, төбәк («Зур Идел», 1974, 1980, 1985 һ.б.), бөтенроссия (автономияле республикалар рәссамнарының әсәрләре, Мәскәү, 1971), халыкара («Китап – 77» бөтендөнья күргәзмә-ярминкәсе, 1977) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1980 (Минзәлә шәһәре), 1984, 1988, 1995, 1996, 1998, 1999, 2002, 2003, 2005, 2006, 2008, 2009 (вафатыннан соң) (Казан) һ.б. елларда уздырыла.

Әсәрләре ТР Милли һәм Дәүләт сынлы сәнгать музейларында, Габдулла Тукай әдәби музеенда, ТР Милли китапханәсендә (Казан), Лодзь Сынлы сәнгать музеенда (Польша), Казанның 2 нче татар гимназиясендә, район мәктәпләрендә саклана.

Хезм.: Заман көзгесе = Зеркало времени = Mirror of the time: графика[альбом]. Казан, 2006.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ЗАҺИДУ́ЛЛИН Илдус Котдус улы (01.01.1963, Татарстанның Балтач районы Яңгул авылы), тарихчы, педагог, тарих фәннәре докторы (2007).

Казан университетының тарих факультетын тәмамлаганнан соң, 1985–1988 елларда Балтач районы Түнтәр урта мәктәбендә укыта. 1993 елда Россия Фәннәр академиясе Казан Гыйльми үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында аспирантура тәмамлый, 1990 елдан фәнни хезмәткәр булып эшли. 1993–1997 елларда — Татар көллияте (1996 елдан — Татар гуманитар институты) директоры, институтның беренче ректоры, 1997–1998 елларда — проректоры. 1998 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында урта гасырлар тарихы бүлеге мөдире (бүленеп, 2006 елда — Россия ислам университеты ректоры), 2015 елдан — яңа заман тарихы бүлеге мөдире. 2021–2022 елларда — ТР Дәүләт архивы карамагындагы «Гасырлар авазы = Эхо веков» журналының баш мөхәррире. 2022 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

Хезмәтләре татар халкы, Россия империясе хакимиятенең дини һәм милли сәясәте һәм Россиядә беренче тапкыр халык исәбен, шул җәһәттән татарларның санын алу тарихына, Россия империясе чорында татар шәһәр

җәмгыятьләре, ислам дине институтлары һәм Каюм Насыйриның тормыш юлы эшчәнлеген өйрәнүгә карый.



И.К.Зәһидуллин

Казан утлары журналында дөнья күргән «Нәсел шәҗәрәсе кайларга китә...» мәкаләсенең кереш өлешендә: «Насыйри феномены серен — аның көчле һәм алдынгы карашлы нәселендә күзәтәбез», — ди. Мәкаләсенең «Насыйри бабалары» бүлегендә галим: «Каюм Насыйриның ата-бабалары Кече Шырдан авылында һәм тирә-якта билгеле кешеләр була. Каюмның гаиләсендә ата-бабаларны белеп һәм хөрмәтләп кенә калмыйлар, аларны балалар тәрбияләгәндә үрнәк итеп тә куялар», — дип яза. Каюмның этисе Габденнасыйр Хөсәеновның татар халкының тарихы һәм этнографиясе белән кызыксынуы, әлеге фәнни юнәлешләр буенча материаллар барлавы, ул чорда Идел-Урал төбәгендә яшәгән мөселман җәмәгатьчелегендә бәхәсле булган ястү намазына мөнәсәбәтле трактатлары (аларда ястү һәм тәрәвих намазларының кирәклеген исбат иткән), фарсы фикер иясе Сәнаиның (1080–1130) «Тәбәкат әл-хаҗәт» («Мөһим эшләр тупланмасы») китабына шәрехләр һәм тәнкыйть характерындагы хезмәт иҗат итүе һәм башкалар турында сөйли. И.Зәһидуллин, үз фикерләренә дәлил буларак, К.Насыйриның этисе турында язган хатирәләреннән бер өзек китерә: «Заманның голямәсе иде. Фарси һәм гарәби язуга маһир иде. Хәзердә үз кулымнан чыккан егерме бишләп китаплар бар». Габденнасыйрның, татар авылларының эпиграфик (каберташ) һәйкәлләрен өйрәнеп, алар турындагы мәгълүматларны дәфтәренә теркәп баруы мәгълүм булуны искәртә.

И.Зәһидуллин мәгърифәтче галимнең татар тарихындагы урынын бәяләп: «1860 елда, татар зыялылары арасында беренче булып, дин кардәшләренең татар халкы булуын әйткән, милләт формалашуга хезмәт иткән кеше дә — Каюм Насыйри икән», — дип яза.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Мөфтиләр һәм казыйлар (Мәхкәмәи шәргыя (1788–1917) рәисләре һәм әгъзалары турында очерклар). Казан, 2021; Габденнасыйр Хөсәеновның балалары // Казан утлары. 2024. №8; Каюм Насыйриның нәсел-нәсәбе // Казан утлары. 2024. №7; Мусульманское богослужение в учреждениях Российской империи: (Европейская часть России и Сибирь). Казань, 2006; Исламские институты в Российской империи: мечети в европейской части России и Сибири. Казань, 2007; Татарское национальное движение в 1860–1905 гг. Казань, 2014; Татары Волго-Уральского региона в материалах правительственной статистики (вторая половина XVI — начало XX. в.). Казань, 2021; Учебно-методическая и научная деятельность Каюма Насыри в православных духовных учебных заведениях Казани в 1855–1870 годы // Вестник Марийского государственного университета. 2024. Т.10. №2; Великий татарский просветитель Каюм Насыри. Казанэ, 2024.

Әд.: Загидуллин Ильдус Котдусович: Библиографический указатель трудов. К 60-летию со дня рождения. Казань, 2023; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиографический словарь. Казань, 2004. Т. 2.

ЗӘЙНУ́ЛЛИН Габделҗәмил (Җәмил) Габделхак улы (11.07.1946, Беренче Май (хәзерге Чирмешән) районы Иске Кади авылы – 15.05.2020,

Казан), шәркыятьче галим, филология фәннәре докторы (1999), профессор (2000), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2004). «Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

Ташкент университетының Көнчыгыш факультетын тәмамлаганнан соң (1974), Казан университетында: 1994 елдан Көнчыгыш телләре кафедрасы мөдире; 2000 елдан Казан (Идел буе) федераль университеты Көнчыгышны өйрәнү институтының беренче директоры; гарәп, фарсы, үзбәк, иске татар телләре, гарәп әдәбияты укытучысы.

Хезмәтләре 16–20 йөз гарәп-фарсы-төрки чыганакларына, 18–20 йөз татар дини әдәбиятына, гарәп, фарсы, иске татар телләрен укыту методикасына карый. Коръәнгә гарәп һәм татар телләрендәге аңлатмаларны тикшерә. «Шәрык алынмалары сүзлеге» авторы. Урта мәктәпләр өчен гарәп теле дәреслеге, 16 йөз татар әдәбияты буенча уку ярдәмлекләре, шул исәптән «Әдәп-әхлак дәресләре: уку ярдәмлеге»н әзерли.

«Дөрес юлдан барырга ниятләгән адәм балалары өчен ярдәмлек буларак тәкъдим ителгән шушы китапны кулына алып, укучы шәфкатьлелек юлына басар, ялгыш адым ясаудан тыелып калыр, кешегә даим дустанә мөнәсәбәттә булыр» дигән максат белән башкарылган әлеге хезмәтендә Г.Зәйнуллин 11 гасыр фарсы әдәби ядкәре: Кәйкавус бине Искәндәр бине Кабус падишаһның үз улына нәсыйхәтләре рәвешендә язылган, кырык дүрт бүлектән (бабтан) торган «Кабуснамә» әсәренә — мәгърифәтче әдип Каюм Насыйри тарафыннан Госманлы төрек теленнән тәрҗемә ителеп, 1882 елда Казанда бастырып чыгарылган, татар дөньясына «Кабуснамә тәрҗемәсе» буларак билгеле китапның аерым бабларына да мөрәҗәгать итә. Галим әлеге китапка анда әдәп-әхлак темалары зур урын алып тору сәбәпле аерым игътибар бирә. Әдәби әсәр булып саналса да, «Кабуснамә тәрҗемәсе»нең баштагы дүрт бабы дини хасиятләргә багышлана: Аллаһы Тәгаләнең барлыгын һәм берлеген танырга, аңа турылыклы булырга, пәйгамбәрен яратырга һәм Аллаһка шөкер итәргә өнди: «Аллаһка һәм аның рәсүленә буйсыныгыз! Бу сезнең беренче үтәргә тиешле бурычларыгыздан («Нисаә» сүрәсе, 59 аять). «Кабуснамә тәрҗемәсе»ндәге хикәятләрдә ата-ананы хөрмәтләү бурычы беренче урынга куела. Балаларның ата-анага лаеклы хөрмәт күрсәтергә бурычлы булулары булулары турында әйтелә: «Аларга «уф» дип тә, кычкырып та сүз әйтмә. Син аларга карата тәмле телле бул, зур хөрмәт күрсәт» («Бәни Исраил» сүрәсе, 23 аять). Г.Зәйнуллин К.Насыйриның әлеге аятькә карата: «Бу аяте-кәримнең күп төрле тәфсире, аңлатмалары бар, ләкин бер тәфсирдә күрдем: иң беренче бурыч — ата-ана хакы дип аңлатыла. Бала ата-ана хөкеменә разый булырга тиешле», — дигән сүзләрен китерә.



Г.Г.Зәйнуллин

Уку ярдәмлегендә «Кабуснамә тәрҗемәсе» хикәятләре: кешене бизи торган күркәм сыйфатлардан белемле һәм һөнәрле булу, сүз сөйли белү, үзеңне тоту, тыйнаклык һәм ашау-эчү тәртибе, шәраб эчү, кунак чакыру, шаяру, уен-көлке сөйләү, мунчаның файдасы һәм зыяны, йоклауның файдасы һәм зарары, мал-мөлкәт туплау, өйләнү һәм ир баланы тәрбияләү турындагы

киңәш-нәсыйхәтләр аерым бүлекләр итеп бирелә.

Галим әхлак тәрбиясенең төп нигезе итеп хезмәт тәрбиясен ала. Дәлилләрендә әлеге юнәлештә күп хезмәт куйган мәгърифәтче әдип, «Китаб- әт-тәрбия» авторы К.Насыйриның: «Кеше хезмәттән һәм кайгыртудан аерылмаска тиеш. Әгәр дә тормышта канәгатьләнү хисе кичерәсең килсә, үз хезмәтең белән яшә. Чөнки хезмәттән башка канәгатьләнү хисе тумый», — дигән фикеренә таяна.

Хезм.: Гарәп язуы нигезендә татарча әлифба. Казан,1989; Шәрык алынмалары сүзлеге, Казан, 1994; Кәлилә вә Димнә. Борынгы татар әдәби истәлеге. Казан, 1996; XVIII–XX йөз башында татар рухани әдәбияты. Казан, 1998; Әдәп-әхлак дәресләре: уку ярдәмлеге. Казан, 2014; Татарская историческая писменность на основе арабской графики. Казань, 1998; Персидский язык. Казань, 2003.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ЗӘКИ́ЕВ Мирфатыйх Зәки улы (14.08.1928, Татарстанның Бөгелмә кантоны Зәйпе авылы (хәзер Ютазы районындагы юкка чыккан авыл) – 18.08.2023, Казан), тел галиме, филология фәннәре докторы (1963), профессор (1964), җәмәгать эшлеклесе. ТР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1991), ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1970, 1976). Халыкара төрки академиянең Татарстан бүлеге академик-секретаре. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994).

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли (1960 елдан татар теле белеме кафедрасы мөдире, 1964 елдан — профессор). 1965–1986 елларда Казан педагогия институтында: проректор, 1967 елдан ректор, бер үк вакытта татар теле белеме кафедрасы мөдире. 1986 елдан — СССР



М.З.Зәкиев

Фәннәр академиясе Казан филиалы, 1991 елдан —Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәге, 1993 елдан — ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм тарих институты, 1996 елдан — ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры; 2001 елдан шунда ук тел белеме бүлеге мөдире, 2008 елдан — лексикология һәм диалектология бүлеге мөдире. 1980–1990 елларда — ТАССР Югары Советы рәисе. Татар энциклопедиясенең Баш гыйльми мөхәрририяте әгъзасы.

Хезмәтләре татар теле синтаксисы, этнолингвистика, тел сәясәте, милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә карый. Тюркологиядә беренчеләрдән булып төрки морфонология нигезләрен ачыклый, татар телендә эш-хәлнең үтәлү дәрәҗәсен белдерүнең деривацион-грамматик системасын тасвирлый, төрки телләрдә килешләрнең күплеген билгели. Болгар-татар эпиграфикасын, төрки-татар әдәби әсәрләренең тел һәм стиль үзенчәлекләрен тикшерә. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы. 3 томлы «Татар грамматикасы» (1992–1993) авторлар коллективының фәнни җитәкчесе. 1990 еллар ахырында татар халкының тел тарихы мәсьәләләренә һәм төрки-татар этногенезына багышланган хезмәтләр нәшер итә.

М.Зәкиевнең Каюм Насыйриның татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеген яктырткан мәкаләләре бар, шулар арасында «Советская Татария» газетасында басылган «Милләт теленең чишмә башында: Каюм Насый-

риның тууының 150 еллыгына карата» (1975), «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» (1976) җыентыгында урнаштырылган «К.Насыйри һәм хәзерге милли татар теле формалашу» мәкаләләрендә галимнең милли телне камилләштерүдәге эшчәнлеген өч яссылыкта — милли тел формалашуның теоретик мәсьәләләре өлкәсендә тикшеренүләр, әдәби нормалар урнаштыруда катнашу, аларны гамәлгә ашыру юнәлешләрендә карарга тәкъдим итә, аның телнең милли лексика, орфоэпика, фонетика, морфология һәм синтаксис нормаларын эшләргә керешүенең сәбәпләрен — тормыш, капиталистик мөнәсәбәтләр үсешен, гомумхалык нормаларына якын яңа милли әдәби нормаларны булдыруга алынуының асылын милләт үсешенең әдәби телне гомумхалык сөйләм нормаларына якынайту ихтыяҗын тирән аңлауда күрә; К.Насыйриның милләтләр оешуга кадәрге чорда кулланылган әдәби телне төп өч төрки әдәби телгә — бохаралылар, хивалылар, үзбәкләр, төрекмәннәр, каракалпаклар һәм кыргызлар арасында таралган көнчыгыш яки чагатай, Госманлылар империясе төрекләре аралашкан көнбатыш яки госманлы, Казан татарлары, мишәрләр, башкортлар, Кырым һәм әзәрбайҗан төркиләре кулланган урта яки татар телләренә бүлүен искәрә; аның телне иҗтимагый күренеш, һәркем өчен дә аңлаешлы гомумхалык телен өйрәнүдән гайре җәмгыятьнең киләчәк үсеше мөмкин түгел, үсеп килүче буын әлгәрләрнең тәҗрибәсен үзләштерү өчен телне өйрәнергә тиеш дигән фикерен ассызыклый, милли тел сүзлеге составын ике (татар сүзләре һәм гарәп-фарсы алынмалары) катламга бүлеп, гомумтөркител тарафдарларына каршы чыгып, мөстәкыйль татар теле тәгълиматын алга сөрүен, тел белеме өлкәсендәге хезмәтләрен югары бәяли, «Татар телен өйрәнү өчен гамәли кулланма» (1857) дип аталган уку ярдәмлеге авторы Мөхәммәдгали Мәхмүдовны (1824–1891) исәпләмәгәндә, К.Насыйрины милли татар телен фәнни әйләнешкә кертүнең пионеры дип атый.

Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Төрки-татар этногенезы. Мәскәү–Казан, 1998; Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан, 2008; Современный татарский литературный язык: Синтаксис. М., 1971; К.Насыри и формирование современного татарского национального языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Татары: проблемы истории и языка. Казань, 1995; История татарского народа (этнические корни, формирование и развитие). М., 2008; Türklerinve Tatarlarınkökeni. Ist., 2007.

Әд.: Академик Мирфатых Закиев. М., 1998; Тенишев Э.Р., Ганиев Ф.А., Юсупов Р.А. Мирфатых Закиевич Закиев // Советская тюркология. 1988. № 5; Hatice Sirin. Prof. Dr. MirfatihZekiyev (Hayatı ve-Eserleri) // Türk Dünyası. Dil ve Edebiyat Dergisi. 2003. № 16.

И.Х.Хәлиуллин.

ЗӘРКӘНЧЕЛЕ́К, һөнәрчелекнең бер төре. 19 йөздә – 20 йөз башында Казан губернасында киң таралыш ала. Бу кәсеп белән 19 йөздә башлыча татарлар, аеруча Казанда, Казан артында, Казан, Лаеш, Мамадыш һәм Чистай өязләрендә яшәүчеләр шөгыльләнә. 19 йөз уртасы — татарларда әлеге һөнәрнең чәчәк аткан вакыты; тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, бизәнү әйберләренә булган җирле ихтыяҗны күпчелек очракларда татар осталары канәгатьләндерә.

19 йөз ахырында руслар яшәгән төбәкләрдә — Лаеш өязенең Балык Бистәсе, Тәтеш өязенең (хәзерге Кама Тамагы районы) Богородское авылларында, Тәтеш шәһәрендә дә үсеш ала. Рус осталарының күпләп җитештергән әйберләре сыйфат ягыннан татарларныкыннан түбәнрәк була, шунлыктан арзанрак бәядән сатыла. Балык Бистәсе осталары югары сыйфатлы әйберләр дә эшлиләр, һәм аларга чит илләрдә дә (Германия, Бөекбритания, Англия, Америка) ихтыяҗ зур була. Татар осталары күбесенчә алтын һәм көмеш, еш кына алтын йөгертелгән көмеш белән эш иткән. Кою, чүкү, уеплау, каралту, җепкыр, шулай ук бөртекләү, кырлау алымнары кулланганнар. Беренче ике алым гадирәк һәм арзанрак әйберләр (тәңкәсыман аеллар, жетоннар, асылмалар) эшләгәндә кулланылган. Беләзекләр һәм йөзекләр ясаганда уеплау һәм каралту ысуллары бергә кушып башкарылган. Җепкыр, бигрәк тә аның татар осталары гына булдыра ала торган күпертмә яки рельефлы үрнәкләре аеруча матур, катлаулы һәм зиннәтле була. Бизәкләү өчен асылташлар һәм ярымасылташлар кулланылган, зәңгәр һәм яшел, сирәгрәк сары һәм кызыл төсмерле минераллар өстенлек иткән. Һөнәрчелек белән, асылда, гаиләнең барлык әгъзалары да мәшгуль булган. 1911 елда Казан губернасында зәркәнчелек белән 290 кеше (шул исәптән 109 рус) шөгыльләнгән.

Зәркәнчелек эшләнмәләренә ихтыяҗ арту һәм шуның нәтиҗәсендә әлеге һөнәрнең үсеше аңа кагылышлы хезмәтләр тууга сәбәп була. 1900 елда Казан университеты нәшриятында Каюм Насыйриның анодлаштыруга, ягъни металл эшләнмәләрне даими гальваник электр тогы ярдәмендә затлырак металлар белән каплатуга багышланган 29 бүлектән торган 33 битле «Санаигы голфания» әсәре дөнья күрә. Аерым алганда, автор көмешләү, бакырлау аша яки турыдан-туры алтынлау, җизләү, никельләү, тимерләү, тимерне бакырлау, аны бронза белән каплату, мәгъдәнгә ману һәм башка эшләр өчен таләп ителгән матдәләрнең нисбәтен, аларның башкарылу үзенчәлекләрен (калып ясаудан башлап) тәфсилләп бәян итә. Мәсәлән, алтынлау: «Туп-туры тимер нәрсәне алтынлау, ягъни әүвәлдән бакырламаенча: 1000 өлеш суда 50 өлеш фосфорный кислый натр, 13 өлеш натр кибрите, 2 өлеш хлористый алтын, 0,5 өлеш циан калий. Бу хәүзның хәрарәте 50–80 дәрәҗә булырга кирәк»; көмешләү: «Моның өчен көмеш хәүз хәзерләмәк кирәк, 6 2/3 килеш хаҗәре 500 өлеш йодистый калий, 1000 өлеш су — бу хәүз бик йомшак заребене теләйдер. 10 дәкыйкадә, күп булса 30 дәкыйкадә көмешләнеп йетәдер һәм бик һәйбәт буладыр... Бу хосуста мәүсаль дигәнемез көмеш такта кирәк. Әгәр дә ул мәүсаль өстенә йод чыга башласа һәм мәхмутны бәнәвишәви [шәмәхә] төс алса, хәүзга едкий калий изеп тамчы-тамчы тамызырга кирәк. Әгәр көмешләмәк нәрсәнең көмеше килешмәсә, төзәтергә мөмкин яки көмешне яңадан алырга мөмкин»; никельләү: «Һәрбер нәрсәне никель белән япмак мөмкин, ягъни бакырдан, җиздән, тутыядан, ак кургашындан, тимердән, чуеннан мәгъмүл нәрсәләрне һәммәсен никельләмәк мөмкин...Җизне, бакырны вә гайриләрне никельләмәк өчен «ибкиле» [икеле] кибритле никель аммиак тозы 10 өлеш, кибрит хамиз аммиак тозы 2 өлеш, кибрит никель аммиак 300 өлеш суда изелә, бу тозлар кайнар суда изелер, әмма хәүз салкын кирәк. Янә тимергә, чуенга, корычка, янә башка төрле мәхмутлар кирәк: мәсәлән, 10 өлеш кибрит хамиз тозы, 1,5 өлеш кибрит хамиз аммоний, 240 өлеш су...»; гальван

гамәле белән тимерләү: «Әмма бу гамәл башкаларына нисбәтән мөшкелрәктер — яхшырак шулдыр ки: 10 өлеш тимер куфарыз, 10 өлеш кибрит хамизе аммоний, 5 өлеш нәшадыр, 50 өлеш су, янә хәүзга берничә тамчы кибрит...»

Р.К.Рәхимованың 2002 елда нәшер ителгән «Каюм Насыйриның «Санаигъ галвания» китабы: транслитерация, лексика һәм сүзлек» хезмәтендә галимнең әлеге әсәренең сүзлек составы һәм сүзләрне куллану үзенчәлекләре, әсәр ахырындагы электр химиясе һәм гальваникалаштыру буенча кайбер терминнарның рус-гарәп сүзлеге тикшерелә, гарәп имлясындагы оригинал тексты, аның кириллицада шул чор татар теленә һәм хәзерге татар теленә күчермәләре тәкъдим ителә.

Чыг.: Насыйри Габделкаюм. Санаигы голфания. Казан, 1900.

Әд.: Рахимова Р.К. Книга Каюма Насыри «Санаигъ галвания»: транслитерация, лексика и словарь (к столетию издания книги «Санаигъ галвания» (1900–2000) и смерти Каюма Насыри (1902–2002)) = Каюм Насыйриның «Санаигъ галвания» китабы: транслитерация, лексика һәм сүзлек («Санаигъ галвания» китабының басылып чыгуына (1900–2000) һәм Каюм Насыйриның үлүенә (1902–2002) йөз ел тулуга багышлана). Казань, 2002.

И.Х.Хәлиуллин.

«ЗИРАГА́ТЬ ГЫЙЛЕМЕ́» («Зирагать гыйлеме, ягъни иген икмәк вә ашлык сачмәк, вә җимеш бакчалары әхйа кыйлмак бәянында бер яңа фәндер» — «Игенчелек гыйлеме»), агрономия буенча кулланма. Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1892 елда Казан университеты басмаханәсендә бастырыла.

Китапта үсемлекләр үсәр өчен тиешле җирнең хосусиятләре, су, җылылык, яктылык, һаваның нинди роль уйнаганлыгы бәян ителә. Аерым алганда җир турында болай диелә: «Йирнең өстендәге ошбу кара туфракның калынлыгы бер аршин кадәр йирләр бардыр ки, нәбататны [үсемлекләрне] үстермәк вә булдырмак хасияте ошбу кара туфрактыр. Гяһан [кайвакыт] ул хасият йирдә бетеп китәдер. Бу хасиятне яңадан хасил итмәк өчен, тиресләмәк дигән гамәлне тапмышлардыр».


(زراعت علمی)

يعنى

ايكون ايكنك - زاغك سليمك - وجيش باشجيلرى

امبا قبلق بيانده، بر بانكا قدر

عبد القيوم عبد الناصر اوغلى تنك استراباندان

قزان ... ده

Домашнюю цензуру. Казань, 25 сентября 1892 г.

بوكتابنك باصمه‌سنه رخصت برلدى شهر قزان ده ل ۲ نجى

سپتابرده ۱۸۹۲ نجى يلده

Центральная научная библиотека КазНЦ РАН

Библиотека ЕИ

بوكتاب باصمه اولنيدر قزان اونيورسيتيتنك طبع خانه‌سنده

۱۸۹۲ نجى يلده

Казань. Типо-литография Императорскаго Университета. 1892 г.

К.Насыйри. «Зирагать гыйлеме». Казан, 1892.

Суның әһәмияте «...һәрбер нәбатат суда изелмеш сыек матдә белән тәрбияләнәдер, нәбататның ашы ошбу нәрсәдер», — дип аңлатыла. Җылылыкның үсемлек тамырының туфрактан кирәкле матдәне алудагы, яктылыкның яшел төс хасил итүдәге, һаваның зәгыйфьлеккә китерәүдәге әһәмияте билгеләнә.

Кыскартылган тексты К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енең икенче томында да (1974) урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Зирагать гыйлеме. Казан, 1892.

Р.Ф.Исламов.

«ЗӨБДӘ́Т МИН ТӘВАРИ́ХИ ӘР-РУСЬ», Россия турында тарихи әсбап. Каюм Насыйри тарафыннан язылган һәм 1890 елда Казан университеты басмаханәсендә авторның үз акчасына бастырылган. Ул, рус телендәге тарихи хезмәтләрдән файдаланылып, бик кыска һәм гади конспект рәвешендә башкарылган.

Әлеге хезмәт Россия тарихы белән татар телендә таныштыру максатында



К.Насыйри. «Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь». Казан, 1890.

язылган. Россия тарихының башлангычын К.Насыйри түбәндәгечә аңлата: «...Болар һәммәсе слав ягъни сакалибә нәселеннән иделәр. 862 нче елларда норман халкы килеп, бу сакалибә халкына галәбә [сугыш] кыла башлагач, славян халкы үзләренә баш кеше киреклеген белеп, рус мәмләкәтен биләп тормак өчен швед халкыннан Рюрик дигән адәмне патшалыкка чакырып алдылар вә һәм кенәз ләкабе белән тәлкыйб иттеләр [кушамат тактылар]». Биредә беренче Новгород князе Рюриктан башлап (вафаты 879 елда) Россия императоры Александр II гә (1818–1881) кадәр идарә иткән князьларның, патшаларның тормышы һәм эшчәнлеге бәян ителә. Шулай ук тарихи әһәмияткә ия булган вакыйгалар тасвирлана.

Чыг.: Насыйри К. Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь. Казан, 1890.

Р.Ф.Исламов.

ЗӨЯ́ ӨЯЗЕ́, 1708–1920 елларда Казан губернасындагы административ-территориаль берәмлек. Үзәге — Зөя шәһәре. 1551 елда нигез салынган Зөя кирмәненнән һәм Иделнең уң ярында аның янында урнашкан җирләрдә 19 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Ханлык яулап алынуның беренче ун елында өяз Нугай, Иске Йеркүл, Чуаш, Арча, Алат, Атыз даругаларына бүленешне саклый. 17 йөздә станнарга бүленү кертелә (Каменка, Тау асты, Кирельск, Моратов). 1708 елда Казан губернасы составына керә. 1719 елда — Зөя провинциясенә, 1781 елда Казан наместниклыгына беркетелә.

Өяз губернаның үзәк өлешендә урнаша. Төньяктан һәм көнчыгыштан — Казан өязе, төньяк-көнбатыштан — Чабаксар, көнбатыштан — Цивильск, көнчыгыштан — Лаеш, көньяктан Тәтеш өязләре белән чикләшә. Идел, Зөя, Гөбенә, Бәрле, Имерлей һәм башка елгалар белән сугарыла. Мәйданы — 2,8 мең кв. чакрым. Халкы — 126,6 мең кеше, шул исәптән руслар — 68,7%, татарлар — 30% (1897). 11 волостьтан тора.

Өяз халкы игенчелек (арыш, солы, бодай, арпа һ.б.), бакчачылык, балык тоту, известь чыгару һәм башка һөнәрләр белән шөгыльләнгән. Өяздә керосин заводы, шырпы фабрикасы эшләгән. Сату өчен ашлык, җитен орлыгы, гипс, известь җитештерелгән. 19 йөз ахырында өяздә 48 башлангыч мәктәп, 28 чиркәү-приход һәм укырга-язарга өйрәтү мәктәпләре, 3 Изге Гурий борадәрлеге миссионерлар мәктәбе,

45 татар мәктәбе һәм мәдрәсәсе, 1 татар училищесы була.

Зөя өязе — Каюм Насыйриның кече ватаны (Югары Шырдан (кара: *Кече Шырдан*) авылында туа). Мәгърифәтчегалим туган ягына кайтып йөри, өязнең хәзерге вакытта ТРның Апас районындагы Борнаш, Кормаш, Кайбыч



районындагы Борындык, Яшел Үзән районына керүче Айдар, Бакырчы, Бәчек, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Мулла Иле, Норлат, Кече Шырдан авылларында булып, аларның кайберләренең зиратларында сакланган борынгы кабер ташларындагы текстларны башлап укый; җирле халыктан сораштырып, халык авыз иҗаты әсәрләрен (әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, җырлар, бәетләр, сынамышлар) җыйнап туплый, тәүге мәртәбә аларны системага салырга омтылыш ясый, фольклор әсәрләренә багышланган «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары», «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)» (28 табышмак, 244 мәкаль, 145 җыр), П.А.*Поляков* белән автордашлыкта язган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» (11 әкият) хезмәтләрендә һәм календарьларында бастыра, «*Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият*»та (27 табышмак, 315 мәкаль һәм әйтем, 117 җыр, 3 бәет) һәм башка әсәрләрендә куллана.

1920 елда Татарстан АССРы төзелгәч, өяз таратыла, аның нигезендә Зөя кантоны оештырыла.

Әд.: Зөя өязе // Татар энциклопедиясе: 6 томда. Казан, 2010. 2 т.

И.Х.Хәлиуллин.

И

ИБӘТУ́ЛЛИНА Мәсхәпҗамал (1885, Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылы – ?), колхозчы, Каюм Насыйриның авылдашы һәм аның турында истәлек сөйләүче.



М.Ибәтуллина

М.Ибәтулланың Каюм Насыйри турындагы истәлекләрен 1945 елда фольклорчы Хәмит *Ярми* язып ала. Бу истәлек-хатирәләр 1948 елда К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган җыентыкта басыла. Ул заманында мәгърифәтче галим белән аралашуы, аның балалар яратуы, авылында мәктәп салдыртуы, үзенең аның китапларын яратып укуы турында тәфсилләп яза: «...Каюм абзый авылга кайткач, без кечкенә балалар-кызлар җыелышып, түбән урамга төшеп китә торган идек. Ул, без җыелып килгәнне ишетеп, капка алдына чыга иде дә: — «я, биегез әле!» — дип, безне биетеп-җырлатып безгә акча биреп җибәрә торган иде. Гаптелман абзыйларны, Хәбирә апаларны да биетеп-җырлатып карый торган иде. Каюм абзый мәктәп салдырган. Ул вакытта безнең Югары Шырдан авылында кызлар мәктәбе юк иде, без 30–40 кыз абыстай өенә җыелып укып азаплана идек. Мин Каюм абзый язган китапларны, хикәяләрне бик яратып укыйм...» — дип искә ала. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Ибәтуллина М. [Каюм Насыйри турында истәлекләр] // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ИБРАҺИ́МОВ Галимҗан Гыйрфан улы (28.03.1887, Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе (хәзер Башкортстан Республикасы Авыргазы районы) Солтанморат авылы – 21.01.1938, Казан), язучы, галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог, журналист. Хезмәт Батыры (1928).

Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә һәм башлангыч рус мәктәбендә ала. 1898–1905 елларда — Оренбург шәһәрендә Вәли мулланың кадими мәдрәсәсендә, 1906–1908 дә «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1909 елда Казанга килә, татар көндәлек басмалары белән хезмәттәшлек итә. 1912 елда Киевка китә, анда мөселман студентлары җәмгыяте эшендә катнаша, аларның Бөтенроссия корылтаен әзерләвенә кушыла. Сәяси эшчәнлеге өчен 1913 елның 17 апрелендә кулга алына. Шул ук елда, төрмәдән азат ителгәннән соң, Казанга кайта, «Аң» журналының җаваплы сәркатибе булып эшли. 1914 елда кабат Киевка китә, аннан Уфага кайта: 1915–1917 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укыта.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң иҗтимагый-сәяси тормышта активлык күрсәтә. 1917 елда язучы Фатыйх Сәйфи-Казанлы һәм журналист Шәриф Сүнчәләй белән бергә «Ирек» газетасы чыгара. Татар-башкорт мөселман сул эсерлар партиясен оештыручыларның һәм аның җитәкчеләренең берсе. 1917–1918 елларда — Милләт Мәҗлесе һәм Учредительләр җыены депутаты. 1918 елда Мулланур Вахитов һәм Шәриф Манатов белән бергә РСФСР Милләтләр эшләре халык комиссариаты каршындагы Эчке Россия Мөселманнары эшләре комиссариатын оештыруда катнаша. 1919–1920 елларда — Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, бер үк вакытта РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында матбугат бүлеге редколлегиясе җитәкчесе һәм «Кызыл Шәрекъ» журналы хезмәткәре. 1920 елдан ТАССР Мәгариф халык комиссариатында эшли. «Безнең юл» һәм «Мәгариф» журналларын оештыручыларның берсе һәм мөхәррире. 1925–1927 елларда — *Гыйльми үзәк* рәисе, бер үк вакытта Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы рәисе. Авыру сәбәпле 1927 елдан Г.Ибраһимов актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлектән читләшә.Гомеренең соңгы елларын Кырымда уздыра, шунда, «Уң троцкийчы милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы» эшендә катнашуда гаепләнеп, кулга алына. Каты авырган язучыны Казанга китерәләр, ул төрмә хастаханәсендә вафат була. Соңыннан аклана.


Иҗатына башта ук чынбарлыкка романтик мөнәсәбәт хас була. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Гыйшык корбаннары» (1908) исемле беренче хикәяләрендә һәм «Татар хатыны ниләр күрми» (1909, рус телена тәрҗемәдә «Татарка», 1935) повестенда татар мәдрәсәләрендә иске ысул белән укыту һәм тәрбия оештыру, яшь буынны тормышка әзерләүдәге кимчелекләр кискен тәнкыйтьләнә, шәхес иреге, хатын-кызларга тигез хокуклар бирү мәсьәләләре куела. Аның иҗаты тулы көченә Казанда ачыла. «Яз башы» (1910), «Диңгездә» (1910), «Сөю-сәгадәт» (1911) хикәяләрендә ул гадәти булмаган, көчле рухлы, романтик, кырыс мохит белән туктаусыз көрәштә, үзлексез рәвештә идеал, тормыш мәгънәсен эзләү юлында булган герой образларын иҗат итә. Әдипнең язучылык таланты, тәнкыйди рухлы романтик буларак, «Яшь йөрәкләр» (1912) романында аеруча ачык чагыла.

1912 елдан башлап, социаль проблемаларны тагын да активрак күтәрә, хезмәт кешеләре образларын иҗат итә («Карт ялчы» (1912), «Көтүчеләр» (1913) хикәяләре). Аның социаль каршылыкларга игътибар юнәлтүен соңрак язылган «Табигать балалары» (1914), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914), «Габдрахман Салихов» (1916) хикәяләре дә дәлилли. 1914 елда ук тәмамланып, 1919 елда нәшир ителгән «Безнең көннәр» романында әдип илдәге сәяси-иҗтимагый чынбарлыкны, аның төп вакыйгаларын күрсәтергә, яңа геройлар — яшь революционерлар образларын тудырырга омтыла. Романда шулай ук татар җәмгыятенең күп яклары — мәгарифнең торышы, шәкертләрнең белем бирүне үзгәртү өчен көрәше, татар интеллигенциясенең идея-эзләнүләре, татар хатын-кызларын иҗтимагый-сәяси тормышка җәлеп итү чагылыш таба. «Алмачуар» хикәясе (1922) татар әдәбиятында һәм тулаем ул вакыттагы милли прозада мөһим күренеш була. Анда татар авылы кешеләренең хисләр дөньясы байлыгы һәм кичерешләре яктыртыла.«Тирән тамырлар» романында

(1928) татар халкы тормышының яңа икътисади сәясәт чорындагы социаль-сәяси асылы гәүдәләндерелә.

Әдәби әсәрләр белән беррәттән Г.Ибраһимов бай публицистик һәм әдәби тәнкыйть мирасы калдыра. 1910 еллардагы мәкаләләрендә үк ул милли әдәбиятны үстерүнең принципиаль мәсьәләләрен күтәрә, аның төп асылын «милли рух һәм характер көзгесе» буларак билгели. Әдәбиятның эчтәлеген һәм әдәби формасын баетуда фольклорга зур әһәмият бирә; киң халык массаларын рус, Шәрекъ һәм Европа классик әдәбиятлары хәзинәләре белән таныштыруны татар интеллигенциясенең мөһим бурычы дип саный. Бер үк вакытта татар әдәбият белемендә марксистик-ленинчыл методология кысаларында милли мәдәниятләрнең асылын һәм үзенчәлекләрен, пролетар диктатура шартларында аларның үсеш перспективаларын тагын да тирәнрәк өйрәнүгә омтылышлар ясый («Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?», 1927).

Г.Ибраһимов — Каюм Насыйрины өйрәнүгә, аның хезмәтәрен танытуга зур көч куйган шәхесләрнең берсе. Гыйльми үзәкнең К.Насыйриның вафатына 20 ел тулу нисбәтеннән 1922 елның 2 сентябрендә аны искә алу көнен үткәрү турындагы карары нигезендә төзелгән өч кешелек комиссия (Г.Ибраһимов (рәис), Сәлах Атнагулов, Газиз *Гобәйдуллин*) әдип хакында мәҗмуга әзерләү чарасына керешә. Алар, К.Насыйрины белгән кешеләргә мөрәҗәгать итеп, кулларында материаллар, язулар, хатирәләр, китаплар, рәсемнәр һәм башка әйберләр булган кешеләрдән ярдәм итүләрен үтенәләр. Нәтиҗәдә, 1922 елда «Каюм Насыйри мәҗмугасы...» нәшер ителә. Г.Ибраһимов анда басылган «Каюм Насыйриларның тарихи урыннары» мәкаләсендә: «Безнең өчен мәсьәләнең төбе Каюм бабаның шәхесендә генә түгел, бәлки мәгълүм бер иҗтимагый-икътисади үзгәрешләр тәэсирендә башланмыш мәгълүм бер фикри-әдәби дәвернең беренче баскычында эшләп үткән төрле тарихи куәтләрдәдер», — дип ассызыклап үтә.



Г.Г.Ибраһимов

Г.Ибраһимов әлеге чара уңаеннан «Татарстан» газетасында (1922) «Каюм Насыйриның вафатына егерме ел тула» дип аталган күләмле мәкалә бастыра. Анда ул К.Насыйриның 19 йөздәге уяну дәверендә тел мәсьәләсендәге эшчәнлеген бәяләп: «Татар теле, татарның имлясы, сарыфы, нәхүе, татарның халык әдәбияты, татарның лөгатьләре кебек, гаммәнең яңа тормышка баруында иң көчле, иң мөһим бер коралны эшләп юлга салудан гыйбарәт иде... Насыйриларның әдәби татар теле барган саен көчәеп, яңадан-яңа көчләрне үзенә тартты, эшләтте, зур агымга — елгага әйләнеп, баеп, матурланып, хәзер инде нәзарияте (теориясе), тарихы белән бергә Татар җөмһүриятенең дарелфөнүн мөнбәрләрендә өйрәтелү дәрәҗәсенә килеп иреште», — дип яза.

Г.Ибраһимов җитәкләгән Гыйльми үзәк 1925 елда К.Насыйриның тууына 100 ел тулуны билгеләп үтә. Шул ук елның 15 февралендә Татар дәүләт театрында уздырылган зур җыелышта ул «Каюм Насыйриның тарихи роле» дип аталган доклад белән чыгыш ясый. Гыйльми үзәк коллегиясенең 1925 ел 26 март утырышы карары белән ТАССР Халык Комиссарлары Советы күрсәтмәсе буенча К.Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан аның мәҗмугасын төзү эше Г.Иб-

раһимовка йөкләнә. Аңа юбилярның тууына 100 ел тулуга багышланган материаллар, аның нәшер ителмәгән хезмәтләре керергә тиеш була. «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре» дип аталган мәҗмуга 1926 елда дөнья күрә.


Г.Ибраһимов әсәрләре СССР һәм чит илләрдәге күп кенә халыклар телләренә тәрҗемә ителә. Ижаты казакъ, үзбәк, төрекмән, башкорт һәм башка халыклар әдәбиятлары үсешенә зур йогынты ясый. Казанда 1967 елда СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына (хәзер ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты), шулай ук Казан проспектларының берсенә аның исеме бирелә. Туган авылында музей-йорты ачыла (1987).

Әсәр.: Әсәрләр. 8 томда. Казан, 1974–1987; Әсәрләр. Академик басма. 15 томда. Казан, 2018–2021.

Әд.: Г.Ибраһимов турында истәлекләр. Казан, 1966; Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман. Казан, 2003; Галимҗан Ибраһимов — документларда: 2 томда / төз. Р.Ф.Исламов. Казан, 2020; Мөхәммәдева Г. Олы юл. Казан, 1994; Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1964; Нуруллин И. Путь к зрелости. Казань, 1971; Халит Г. Галимджан Ибрагимов // История татарской советской литературы. М., 1965; Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов. Казань, 1977; Ғимаҙиев Ү. Ғалимьян Ибраһимов — журналист. Өфө, 1967.

ИБРАҺИ́МОВА Фатыйма Исхак кызы (15.03. 1928, Татарстанның Бөгелмә кантоны (хәзерге Лениногорск районы) Кирлегәч авылы – 07.11.2016, Казан), әдәбият галиме, текстолог, филология фәннәре кандидаты (1969). ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1998).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1952), 1962 елга кадәр урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1965 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының (1991 елдан — Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең, 1993 елдан – ТР Фәннәр академиясенең) Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1996–2000 елларда ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли.



Ф.И.Ибраһимова

Хезмәтләре татар балалар әдәбияты тарихына, 20 йөз башы татар язучыларының әдәби мирасына карый. Муса Җәлил (1–4 т., 1975–1976), Галиәсгар Камал (1–3 т., 1978–1981) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша; Мәҗит Гафури (1 т., 1980; 4 т., 1988), Фатих Әмирхан (1 т., 1984), Галимҗан Ибраһимов (9 нчы т., 2000), Гаяз Исхакый (8 нче т., 2001) әсәрләренең аерым томнарын басмага әзерли. «Балалар әдәбияты» (2004) хрестоматиясен төзи.

Каюм Насыйриның замандашлары, татар укымышлылары, дин эшлеклеләре Нуретдин *Ишаевның*, Гарифулла *әл-Чокрыйның*, Мөхәммәтнәҗип *Түнтәринең*, Мөхәммәтхәнәфи *Мозаффарның*, Габдулла бине Таҗетдин *әл-Кәчимиринең*, Насретдин *әл-Хуҗашиның* 1912–1913 елларда «Шура» журналында дөнья күргән истәлек-хатирәләрен гамәлдәге татар графикасына күчереп, «Әдәби мирас» (1996, 3 нче кит.) җыентыгында бастырып чыгара, соңыннан алар галимәнең «Фәнни гомерем мизгелләре» (2012) китабында да урын ала. Алар К.Насыйриның тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнүдә иң объектив чыганаклар булып тора. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Заман белән бергә. Казан, 1971; Каюм Насыйри турында истәлекләр // Әдәби мирас. Казан, 1996. 3 нче кит.; Сабыйларны үз итеп... Казан, 1998; Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы. Казан, 2003 (автордаш); Фәнни гомерем мизгелләре. Казан, 2012.


Әд.: Әмирхан Р. Заман белән бергә (Фәнгә багышланган гомер) // Шәһри Казан. 1998. 13 март; Ислам З. «Язмыш» китабын ачсаң... // Мәдәни җомга. 2003. 19 декабрь; Рәмиев З. Эшчән һәм тыйнак галимә // Мәдәни җомга. 1998. 20 март.

Р.Ф.Исламов.

«ИГЪЛАНА́Т», календарьлар һәм китаплар исемлеге. Каюм Насыйри тарафыннан төзелә һәм 1896 елда Казан университеты басмаханәсендә китап итеп бастырыла.

Китапта 1871–1873, 1882–1897 елларда нәшер ителгән календарьларының һәм сатыла торган утыз сигез китабының [бәяләре белән] кыскача аңлатмалары китерелә. Мәсәлән, календарьларның берсенә шундый аңлатма бирә: «1871 нче елга календарь 68 сәхифәдән гыйбарәт булып, Казан нахиясендә [төбәгендә] бер ел мөддәтендә [вакытында] һәр көн таң белену, кояш чыгу, кояш баю, көннең озынлыгы, сәгатьләр тәфавете [аерымлыгы]; гыйнвар башлары, шәмсия ел хисабы вә камәрия ел башлары, хәтердә тотарлык бәгъзе маддәләр, ярминкәләр, бәйрәмнәр вә мәхкәмәсез көннәр, Русиядә падишаһлык сөргән адәмнәр, падишаһымызның нәселе вә нәсәпләре, почта, тимер юл вә телеграф. Хокук, тиҗарәт (сәүдә), яңа хөкем, паспорт, ярмовой кәгазьләр, акча вә гайреләр. Ибтидаи мәмалик Рус, җәгърәфияи сәясия хакында бер маддә, тәварихтан вә кәзалик Русия җәгърәфиясеннән бераз мәгълүмат вә үткән елларда рузага ни көн керелгәне».

Китаплар турында түбәндәгечә яза: «Әнмүзәҗ» китабы 87 сәхифәдән гыйбарәт. Телемезнең сарыф (морфология) вә нәхү (синтаксис) кагыйдәләре бәянында чыгтай теленнән Мир Галиширнең «Тәхасым әл-лөгатәин» («Тел үзенчәлекләре») дигән китабыннан башка чыгтай шөгъбәләреннән татар теле дигән телемезнең кавагыйдат


اعلانات

اوشبو دفتره فقیر عبدالقیوم ملا عبدالناصر اولغانلنك ۱۸۷۱ نچی یلدان ۱۸۷۲ نچی یلغه قدر تصنیف ایتوب باصدرغان هر قایسی کالیندارلرنك وکتابلرنك تعریفاری مرفرس منزلده بیان قیلنور چونکه فنون شی‌ءدن بعض معلومات یازلیش بولوب مثلا:

Центральная научная библиотека КазНЦ РАН Reference 691

اوشبو اعلانلرنك باصیلمسنه رخصت برلدی. کاتب پیطر بوریده ۲۵ نچی سنتابرده ۱۸۷۱ نچی یلده.

Типо-литография Императорскаго Университета. 1896.

К.Насыйри. «Игъланат». Казан, 1896.

сарфиясе вә нәхүсе (морфология һәм синтаксисы кагыйдәләрен) бәянында бер китап күренмидер иде. Бу дәхи әүвәл мәртәбә дөньяга чыкты 1895 нче елда табыг кыйлдырылды (40 тиен)».

Чыг.: Насыйри К. Игъланат. Казан, 1896.

Р.Ф.Исламов.

«ИҖЁК», хәреф танырга һәм укырга өйрәнү өчен, ягъни Әлифба буларак кулланма. Каюм Насыйри тарафыннан язылып, 1895 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителгән.

Кулланма башланыч сыйныф балаларына атап төзелгән. Әүвәл хәрефләр, аннан соң аларның хәрәкәләр белән язылышы, сүзләр ясалышы бире-

лә. «Әлиф» авазының озынлыгы күрсәтелә. Уку-язу күнекмәләре итеп төрле сүрәләр, төрле очракларда (йокларга ятканда, йокыдан уянгач, бит юганда, бер-бер нәрсәдән курыкканда, ашаганнан соң һ. б.) укыла торган догалар китерелә. К. Насыйри үзе белдергәнчә, «...диянәт кәлимәләре (дин сүзләре) белән баланың теле ачылса вә фән истыйлыхлары (атамалары) белән зиһене ачылса — ул бала өмидлерәктер».

Чыг.: Насыйри К. Иҗек. Казан, 1895.

Р.Ф.Исламов.

ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕ́Р, җәмгыятьнең рухи тормышының һәм рухи җитештерүнең бер өлеше; иҗтимагый аңның кешеләр төркемнәренең мәнфәгатьләренә һәм ихтыяҗларына бәйле, төрле вакыйгаларга һәм социаль чынбарлыкка, шулай ук аерым затларга карата мөнәсәбәтен яктырткан формасы.

Җәмгыять үсешенең барлык (социаль, икътисади, сәяси, мәдәни-рухи, дини, мәгариф һ.б.) өлкәләренә кагыла, аның чагылышы буларак, үзгәрешләр кичерә. Еш кына рәсми хакимият идеологлары алга сөргән тәгълимат нигезләмәләре белән каршылыкка керә. Ачыктан-ачык яки яшерен рәвештә белдерелә. Беренче очракта шәхесләрнең тәгаен карашларында бәян ителә. Яшерен фасылда мәгънә салынган төрле (әдәби, сынлы, декоратив-гамәли сәнгать һ.б.) әсәрләрдә урын ала: сәнгатькәр аларда билгеле бер дәрәҗәдә мөһим исәпләнгән идеяләрне күтәрә (мәсәлән, 20 йөзгә кадәр — Мөхәммәдъяр, Мәүлә Колый, Габдерәхим Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави, Габделҗәббар Кандалый һ.б.); әсәрләрнең таралышы алардагы төп фәлсәфи мәгънәнең массачыл карашлар белән үрелүенә китерә.

19 йөзнең 2 нче яртысында татар халкы тормышына алдынгы карашлар үтеп керә башлый; аерым алганда, мөселманнарның мәгърифәтче-ислахчылык иҗтимагый-сәяси яңарыш хәрәкәте буларак, *җәдитчелек* барлыкка килә. Зыялыларның алдынгы карашлы өлеше аңарда татар җәмгыятен күпгасырлык торгынлыктан алып чыгарга сәләтле интеллектуаль һәм идеологик көчне күрә, шул исәптән әлеге чорда татар демократик фикеренең чишмә башында торган Каюм Насыйри тәмам искергән тормыш рәвешен һәм нигезләрен тамырдан үзгәртү, яңа идея юнәлешләре зарурлыгына төшенеп эш итә; җәдитчелек үзәгендә торган мәгариф системасын яңарту мәсьәләсен яңа ысуллы мәдрәсәләр оештыру юлы хисабына хәл итү белән генә чикләнмичә, татар балаларына рус теле укыту аша үз халкының рус һәм Европа халыклары казанышлары белән таныш киләчәк буынын әзерләү, аны рухи, социаль изүдән йолу бурычын алга куя, гомерен актив мәгърифәтчелек эшчәнлегенә, халык арасында белемнәрне таратуга, шулай ук рус мәдәниятен пропагандалауга багышлый. Аның дөньяга карашлары формалашуда Казан университетында ирекле тыңлаучы сыйфатында укуы, шундагы күренекле галимнәр һәм Казан өязе руханилар училищесындагы, Казан руханилар семинариясендәге укытучылар белән аралашуы хәлиткеч роль уйный. Галим табигать күренешләрен дөньяви яссылыкта шәрехли, шул рәвешле татарларны хорафатлар хакимлегеннән азат итүгә зур өлеш кертә. Әмма җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне аңлатуда, М.К.*Мөхәррәмов* фикеренчә, ул башлыча идеалистик позицияләрдә кала бирә, тарихның эзлекле барышындагы закончалыкларны аңлап бетерми; шулай да, социаль яшәештәге каршылыкларны күреп, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең һәм тәр-

типләрнең асылына тирәнрәк төшенә бара. Аның хезмәтләрендә татар халкының килеп чыгышы, үзбилгеләнүе һәм үзаңы, милли мәдәниятнең үзенчәлеклелеге һәм мөстәкыйльлеге мәсьәләләре яктыртыла, балаларга заманча белем бирүгә, аларны хезмәт белән тәрбияләүгә, рус мәдәнияте казанышлары белән таныштыруга зур игътибар юнәлтелә. Татарларны агартуда К.Насыйри җаваплылыгында нәшер ителгән календарлар (кара: *Каюм Насыйри календарьлары*) зур роль уйный. Аның иҗтимагый фикерләре Мөхәммәдгали *Мәхмүдов*, Габдрахман Ильяси, Габдулла *Тукай*, Мәҗит Гафури, Фатих *Әмирхан*, Галиәсгар Камал, Галимҗан *Ибраһимов*, Мөхетдин *Корбангалиев* һәм башкаларның эшчәнлегенә һәм иҗатына йогынты ясый.

Әд.: Мөхәррәмов М., Абдуллин Я. Күренекле татар галиме һәм демократы // Татарстан коммунисты. 1975. №5; Абдуллин Я.Г. Джадидизм среди татар: возникновение, развитие и историческое место. Казань, 1998; Магдеев М. Учёный Каюм-бабай // Наука и религия. 1975. №2; Мухарямов М.К. Каюм Насыри и его эпоха // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

И.Х.Хәлиуллин.

«ИЗВЕ́СТИЯ О́БЩЕСТВА АРХЕОЛО́ГИИ, ИСТО́РИИ И ЭТНОГРА́ФИИ ПРИ ИМПЕРА́ТОРСКОМ КАЗА́НСКОМ УНИВЕРСИТЕ́ТЕ» («Император Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»), кара: *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*.


«ИМПЕРА́ТОР РУС ГЕОГРА́ФИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́ ЯЗМАЛАРЫ́» («Записки Императорского Русского географического общества»), географик журнал. 1845 елда император Николай I указы белән нигезләнгән Император Рус география җәмгыятенең фәнни басмасы. 1865 елдан «Император Рус география җәмгыяте хәбәрләре» («Известия Императорского Русского географического общества») исеме, 1866 елдан хәзерге исем белән чыгарыла. Журнал материаллары 3 бүлеккә (гомуми география, статистика, этнография) бүлеп нәшер ителә.

Каюм Насыйри татар галимнәре арасында беренчеләрдән булып 1880 елда журналның 6 нчы томында рус телендә үзенең «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» («Поверья и обряды казанских татар») хезмәтен бастыра. Ул өч өлештән тора («Ышанулар», «Сынамышлар», «Мәҗүси йолалар һәм әфсен-өшкерүләр»); анда татарларның мәҗүсилектән калган йолалары, хорафатлары (халык арасында таралган дөнья корылышы турындагы күзаллауларга бәйле булган, дини карашлардан ерак торган ышанулар), галимнең үзе тарафыннан тупланган татар халык әкиятләрендәге уйдырма затлар (судагылар — су бабасы, су иясе, су анасы, юха һәм коры җирдәгеләр — убыр, албасты, өрәк, бичура, өй иясе, абзар иясе, чәчәк анасы, чәчәк иясе, шүрәле, җен, дию пәрие) тасвирлана, «Гөлнәзек» әкияте бәян ителә, әфсен-өшкерүләрдән мисаллар китерелә.

И.Х.Хәлиуллин.

«ИРША́Д ӘЛ-ӘТБИХӘ́» («Иршад әл-әтбихә ила истихзар әл-әтгамә» — «Ашамлык әзерләү буенча кагыйдә»), пешекчелек буенча кулланма. Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1893 елда бастырыла. Ул китапның максатын шулай дип аңлата: «Ошбу «Иршад әл-әтбихә ила истихзар әл-әтгамә» исемле рисаләмез бәла тәкътир [сакчыллык] вә бәла исраф тереклек кылгучы әфәнделәремезгә

бер тәзкирәдер [истәлектер]. Әлбәттә ошбу рисалә кулыңызда булып, бу көн ни нәрсә пешерим дип уйлап торгынча, карап мәзмуны [эчтәлеге] белән гамәл кылсаңыз, һәр көн татлы вә арзанлы тәгам ашамакыңыз мөкаррәрдер [хәл ителгәндер]».



К.Насыйри. «Иршад әл-әтбихә». Казан, 1893.


Китапта ашамлыклар ике төргә бүленә: төп матдәләр һәм тәм бирүче матдәләр. Ашамлыкларны әзерләү, ягъни пешерүysуллары һәм тәртипләре китерелә (су, сөт, май һәм башкалар белән). Беренче ашау белән икенчесенә кадәр вакыт билгеләнә. Тәм бирүче матдәләрнең (тоз, суган, борыч, лимон, серкә, керән һ.б.) ризыкка тиешле күләмдә генә салынырга тиешлеге, артып киткән очракта аларның зарар китерү ихтималы турында әйтелә. Җитмеш төрле ашамлык әзерләү ысулы китерелә. Аларның күбесен әзерләү өчен үзебезнең җирлектә җитештерелгән продуктларны куллану тәкъдим ителә (мәсәлән, икмәк чумарын, тавык кәбабен, кабак боткасын, алма бәлешен, сөтле өйрәне, пылау пешерү өчен). Хәлвә әзерләүнең мондый ысулы күрсәтелә: «Сигез йомырка агы, алты йомырка сарысы, ярты кадак шикәр, ярты чынаяк бәрәңге оны; боларны бергә тәмам яхшылап болгат, катыштыр, шөйлә ки төере калмасын. Бер катыргадан ясаган тартмага салып, могтәдил (уртача) эссегә куй. Анда пешкәч, алып суыт, бер савытка ал, өстенә мөрәбба (кайнатма) ал, дәстарханга (ашъяулыкка) куй».

Икенче мәртәбә китап Исмәгыйль Шәмсетдиновның матди ярдәме белән 1901 елда нәшер ителә. Хезмәтнең кереш өлеше — оригиналда һәм хәзерге татар теленә күчермәсе белән К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1953, 1956) урнаштырылган. 2015 елда ул гамәлдәге татар графикасында һәм рус теленә тәрҗемә итеп тә бастырыла.

Чыг.: Насыйри К. Иршад әл-әтбихә. Казан, 1893; шул ук. Наставления повару. Казань, 2015.

Р.Ф.Исламов.

«ИРША́Д ӘЛ-ӘХБА́» («Иршад әл-әхба ила тәгълим әлифба» — «Укырга өйрәнгәнче әлифба таныту»), хәреф танырга һәм иҗеклəп укырга өй-



К.Насыйри. «Иршад әл-әхба». Казан, 1901.

рәнү өчен әлифба буларак кулланма. Каюм Насыйри тарафыннан төзелә һәм 1901 елда Исмәгыйль Шәмсетдиновның матди ярдәме белән Казан университеты басмаханәсендә 1901 елда нәшер ителә.

Кулланма башланыч сыйныфта укый башлаган балалар өчен төзелгән. Әүвәл ноктасыз һәм нокталы хәрефләр, аннары хәрефләр хәрәкәләр белән китерелә. Хәрефләрдән сүзләр ясалышы өйрәтелә. Күнекмәләр өчен төрле сүрәләр, догалар китерелә. Китап ахырында болай язылган: «...диянәт кәлимәләре [дин сүзләре] белән баланың теле ачылса вә фән истыйляхлары [атамалары] белән зиһене ачылса — ул бала өмидлерәктер».

Чыг.: Насыйри К. Иршад әл-әхба. Казан, 1901.

Р.Ф.Исламов.

ИСӘНБӘТ Нәкый (Закиров Нәкый Сиражетдин улы) (29.12.1899, Уфа губернасының Златоуст өязе Малаяз авылы – 15.09.1992, Казан), язучы, фольклорчы, тел белгече, педагог. ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957, 1959), ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1968), ТАССРның халык язучысы (1986).

Мулла гаиләсендә туа һәм тәрбияләнә. «Хәсәния» (1910–1912, Уфа) һәм «Мөхәммәдия» (1912–1916, Казан) мәдрәсәләрендә белем ала. 1919–1922 елларда читтән торып Уфа Халык мәгарифе институтында, Харьков университетында, Көнчыгыш хезмәт иярләре коммунистик университетында (Мәскәү) укый. Кыска вакытлы педагогия курсларын тәмамлаганнан соң, 1917–1923 елларда Башкортстан авылларында балалар укыта. 1923–1930 елларда — Уфада, 1930, 1932–1937 елларда — Казанда, 1938–1939 елларда — Татарстанның Әтнә районында



Н.С.Исәнбәт

мәктәп һәм техникумнарда татар, башкорт телләре һәм әдәбиятлары, шулай ук башка фәннәр буенча белем бирә, методист, педагогик курслар лекторы булып эшли.

1920 еллар ахырында бер төркем татар-башкорт язучылары белән бергә контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнә, 1929–1930 елларда аклана, ләкин үз хезмәтеннән читләштерелә, шул сәбәпле 1930–1932 елларда Казанда «Спартак» фабрикасында эшли.

1939 елдан — профессиональ язучы. Тәүге әсәрләре 1910 еллар уртасында басыла, алар арасында «Сукбай», «Укытучы кыз» поэмалары, «Рияга каршы», «Күңел ярасы», «Кешелек дөньясы», «Сугыш», «Инкыйлаб» шигырьләре бар. «Чаң» җыентыгына (1925) кергән шигырьләрендә ирекле күмәк хезмәткә, «Эшче Хафиз» (1920), «Днепрострой» (1932), «Нужа бабай» (1950) поэмаларында һәм башка шигырьләрендә хезмәткә, яшьлеккә, мәхәббәткә, табигать гүзәллегенә дан җырлый.

Ул үзен драматург буларак та таныта, 40 дан артык пьеса (драма, трагедия, комедияләр) авторы, алар арасында «Әмирхан хәзрәт» (1916), «Сират» (1919), «Һиҗрәт» (1923), «Пикүләй Шәрәфи» (1929), «Миркәй белән Айсылу» (1935), «Хуҗа Насретдин» (1939), «Идегәй» (1941), «Түләк» (1942), «Җирән чичән белән Карачәч сылу» (1942), «Гөлҗамал» (1944), «Зифа» (1954), «Әбүгалисина» (1959), «Хәйләкәр Дәлилә» (1966), «Кырлай егете» (1965) һ.б бар. Аның пьесалары киң таныла һәм күбесе сәхнәдә зур уңыш белән бара. «Түләк белән Сусы-

лу» операсының либретто авторы (музыкасын Н.Җиһанов яза, 1944).

Халык, ил тарихы темасына тугры калып, Н.Исәнбәт «Болак арты республикасы» (1940), «Мулланур Вахитов» (1944), «Муса Җәлил» (1954) һәм башка әсәрләр иҗат итә. Бөек Ватан сугышы кайтавазы «Рәйхан» (1948) пьесасында чагылыш таба. «Мәрди белән Нәфисә» (1974) драмасында үткән сугыш еллары вакыйгаларына бәя бирелә.

Фольклорчы галим, татар фольклорын җыючы: 28 күчермәгә (вариантка) таянып, «Идегәй» дастанының җыелма текстын эшли; «Татар халык мәкальләре» (1–3 т., 1959–1967), «Татар халык табышмаклары» (1970), «Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен» (1984) җыентыкларын; «Татар теленең фразеологик сүзлеге»н (1–2 т., 1989–1990), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (1–4 т., кулъязма рәвешендә) төзүче.

Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулуга багышланган җыелышта катнаша. Н.Исәнбәтнең шул хактагы һәм галимнең Байназар *Әлминов* тарафыннан язылган портреты тарихына нисбәтле истәлеге түбәндәгечә бәян ителә: «1925 елның февраль аенда Мәдәният йортында (ТЮЗ) мәгърифәтче Каюм Насыйриның йөзьеллыгын үткәрергә булдылар. Тантана башында Шәһит *Әхмәдиев* хөкүмәт исеменнән язылган хатны укыды. Җыелышны Галимҗан *Ибраһимов* ачты. Гали *Рәхим* Каюм Насыйри турында нотык сөйләде. Аерым чыгышлардан Фатих *Әмирханның* сүзләре истә калган. Бәйрәм мөнәсәбәте илә Каюм Насыйриның рәсемен ясаганнар иде. «Бу рәсем белән мин мотлак разый түгелмен!» — диде ул. Фатих ага юбилей уңае белән ясалган Каюм Насыйри рәсеме турында аеруча тәфсилле итеп сөйләде. Рәсемнең авторы Госман *Арсланов* иде. Бу рәсемдә фәкыйрь, мескен кыяфәтле бер кеше, ярым мулла, ярым җәдитче сурәтләнгән иде. Фатих Әмирхан: «Мин Каюм Насыйри китапларын укып үстем. Китабын укыганда аның язучысын да күз алдына китерәсең. Бу рәсем мин күзаллаган галим Каюм Насыйрига бер дә охшамаган», — диде. Шуннан соң президиум: «Каюм Насыйриның яңа рәсемен ясатырга!» дигән карар чыгарды. Ләкин ул рәсем шулай карарда гына килеш кала. 1945 елда, Каюм Насыйриның йөз егерменче еллык бәйрәмен уздырыр алдыннан, Фәннәр академиясенең директоры Мөхәммәт *Гайнуллинның* исенә Фатих Әмирханның егерме ел әүвәл әйткән сүзләре килеп төшә. Һәм Мөхәммәт ага Каюм Насыйриның йөзен ясатырга тасвирлар эзли башлый». Башта ул Каюм Насыйриның этнография буенча язганнарын укып чыга... Аннан соң Мөхәммәт ага Каюм Насыйриның абзасы Габделхәй белән алышкан хатлары белән таныша. «Габделхәй — Мәскәүдә сабын-парфюмерия кибетләре тоткан бай кеше. Әнә шул Габделхәй Каюм Насыйри өчен Казанда тун тектерергә заказ биргән. «Тунны ничегрәк тегәргә?» дип, агасы Каюмга хат яза. Каюм: «Үз туның төсле булсын!» — ди. Габделхәй Каюм энесенә бер алганда (бер айга) йөз сум банкадан акча алырга рөхсәт калдыра. Каюм Насыйрины мескен итәргә тырышалар. Бер дә мескен булмаган ул. Ярлы да булмаган. Димәк, Каюм Насыйри модный чалбар, байлар гына кия торган яхшы тун кигән. Байназарга мин, Насыйрины әнә шулай затлы итеп тасвирла, дидем. Байназар ясап бетергәч, рәсемне Каюм Насыйриның туган авылы Шырданга алып кайттык. Каюмны күреп белгән картлар әле исән иде, шу-

ларга күрсәттек. Алар: «Менә бу безнең Каюм», — диделәр».

Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, мелальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Ни өчен ни булган, яки утыз ялган: Әкиятләр. Казан, 1956; Кырлай егете: Пьесалар. Казан, 1980; Әсәрләр: 4 томда. Казан, 1988–1989.

Әд.: Әдип һәм галим. Казан, 1969; Әхмәдуллин А.Г. Үзенчәлекле талант турында сүз // Дөреслеккә ирешү юлында. Казан, 1993; Ханзафаров Н. Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан, 1982; Шамуков Г. Нәкый Исәнбәт. Казан, 1959.

И.Х.Хәлиуллин.

«ИСЕРЕКЛЕ́К ЗАМАНЫ́», эчкечелеккә каршы шигырьләр җыелмасы. Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм Хөсәен Шәмсетдиновның матди ярдәме белән Казан университеты басмаханәсендә 1896 елда нәшер ителә.

Китап 1893 елның 20 июлендә Россиядә хәмер эчемлекләр сатуга дәүләт монополиясе кертелгәннән соң дөнья күрә. Аның язылу сәбәбен автор түбәндәгечә аңлата: «Исереклек хәлләре бәянында гыйбрәтнамә, ягъни исерткеч эчкән кешегә үгет-нәсыйхәт вә гыйбрәт ошбу әбъят [бәетләр] бер бичара гаҗизнең эчемлектән бизәр булып монан егерме биш ел мөкаддәм [элек] инша кылынмыш бәетләредер...». Ул «Эчкенең башы», «Яңа эчә башлаганда», «Тәмам исереп беткәч», «Бәян макмыр», «Эчемлектән авыру», «Эчеп эштән чыгу», «Кеше сыйлау», «Эчәргә кызып китү», «Бәян кызлар», «Трахтирга кереп чәй эчү», «Исерткечнең нәсыйхәт бирүе», «Исерек үзен үзе мәлямәт кылганы (орышканы)» дип аталган гыйбрәтле шигырьләрдән тора.



К.Насыйри. «Исереклек заманы». Казан, 1896.

Чыг.: Насыйри К. Исереклек заманы. Казан, 1896.

Әд.: Катанов Н. Исриклик халляры беянында гибрет-наме (Книга примеров относительно обстоятельств пьянства) // Деятель. 1897. № 1.

Р.Ф.Исламов.

ИСЛА́МОВ Рәмил Фәнәви улы (14.09.1958, Башкортстанның Балтач районы Усман авылы), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (2002). ТРның атказанган фән эшлеклесе (2019), Казан мәдәният һәм сәнгать институтының шәрәфле профессоры (2020). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2023).

Башкорт университеты филология факультетының татар-рус бүлеген (1987), СССР Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәге Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының аспирантурасын татар әдәбияты белгечлеге буенча (1990) тәмамлый. Әлеге институтның әдәбият белеме бүлегендә кече фәнни хезмәткәр итеп эшкә калдырыла; 2002

елдан әдәбият бүлеге мөдире, 2007 елдан — директорның фән эшләре буенча урынбасары, 2009 елдан — Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире, 2015 елдан ТР Милли архивында баш белгеч булып эшли. 2016 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында текстология бүлеге фәнни хезмәткәре, 2017 елдан — Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының энциклопедистика үзәгендә баш фәнни хезмәткәр.

Хезмәтләре Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры язма мирасын, аларның мәдәни багланышларын, урта гасырлар төркы шигърияте үсешендә Шәрифнең «Шаһнамә»сен (чыганаклары, шигырь төзелеше һәм стиле) өйрәнүгә карый. Шагыйрьләр Дәрдемәнд һәм Фатих Кәрим, мәгърифәтче галим Каюм Насыйриның тулы библиографияләрен, Акмулланың казакъ телендәге библиографиясен һәм Габдулла Тукайның библиографик күрсәткечен төзи. Шулай ук «Тукайны өйрәнүдә яңа чыганаклар» (2016) хезмәте авторы, «Татар энциклопедия сүзлеге» (1999), 6 томлык рус һәм татар телләрендәге «Татар энциклопедиясе» (2002–2014; 2008–2021), «Габдулла Тукай. Энциклопедия» (2016), ике томлык «Тукай — ядкярләрдә» (2015), ике томлык «Галимҗан Ибраһимов — документларда» (2020), «Борһан Шәһиди — дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, дипломат, галим, язучы» (2020), «Борхан Шахиди — государственный и общественный деятель, дипломат, ученый, писатель» (2021) басмаларының автордашы, «Муса Җәлил — документларда» (2021), «Мифтахетдин Акмулла: тормыш юлы һәм иҗаты» (2022) хезмәтләрен төзүче.

Текстологик юнәлештә «Ахырзаман китабы» (2000), «Кисекбаш» (2000), Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (2000) кебек урта гасырлар әсәрләрен, автордаш буларак, «Мөслимәләрнең Исламияттагы хәлләре» (2000), Зыя Камалиның «Аллаһы гадәләте» (2000) хезмәтләрен гамәлдәге татар графикасында бастырып чыгара.



Р.Ф.Исламов

Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе Каюм Насыйрига багышланган «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык» (2017) китабын төзүче. Анда галимнең тормышын һәм күпкырлы эшчәнлеген яктырткан 12 тематик мәкалә урнаштырылган; аның туганнары, авылдашлары, күреп белгән һәм турыдан-туры аралашкан кешеләр тарафыннан язылган 23 истәлекнең матбугатта басылган һәм архивта сакланган 12 се гарәп хәрефләреннән гамәлдәге татар графикасында беренче мәртәбә тәкъдим ителгән; әти-әнисенә, туганнарына һәм төрле кешеләргә язган, үзенә атап язылган 220 хат төп нөсхәләрдән алынып туплана, шуларның 163 е беренче мәртәбә игълан ителә; китерелгән 21 дәгъватнамә (чакыру кәгазе) галимнең аралашкан даирәсен ачыкларга ярдәм итә; 1922–1925 елларда Татарстан Халык мәгарифе комиссартиатында һәм аның карамагындагы *Гыйльми үзәктә* К.Насыйрига бәйле мәсьәләләр каралган 6 утырыш беркетмәсенең 5 се укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Китапта Р.Исламов тарафыннан мәгърифәтченең тулы библиографиясе урнаштырыла. Көндәлек матбугатта бастырган мәкаләләрендә К.Насыйрины өйрәнү тарихының төрле аспектлары чагылды-

рыла, галим эшчәнлегенең үзенчәлекләре тасвирлана.

2024 елда «Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч»ен төзеп нәшер итә.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «ТАССР төзелүгә 100 ел» медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар. Казан, 1998; Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә Шәрифнең «Шаһнамә»се (Текст һәм чыганаклар. Шигырь төзелеше һәм стиль). Казан, 2001; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч. Казан, 2024.

Әд.: Мансуров З. Хәтер киләчәккә илтер // Ватаным Татарстан. 2017. 28 март; Мансуров И. Сынмый да, сыгылмый да... // Кызыл таң. 2023. 15 сентябрь; Мөхәммәтшин З. Тукай шәхесе ядкярләрдә // Мәдәни җомга. 2016. 26 август; шул ук. Чыганакларда шәхес язмышы // Мәдәни җомга. 2021. 20 август; шул ук. Муса Җәлил — чыганакларда // Мәдәни җомга. 2022. 17 июнь; Нәккаш Н. Тукайга һәйкәл // Мәдәни җомга. 2017. 17 март; Хәйруллин Р. Үткәннәргә карап алга таба // Тулпар. 2008. № 4.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ИСЛА́МОВ Фәнис Фәтхулла улы (23.08.1932, Башкортстанның Яңавыл районы Сибәде авылы – 20.06.2010, Казан), педагог, педагогика фәннәре кандидаты (1973). Халык мәгарифе отличнигы (1989), ТРның атказанган укытучысы (2006).

Казан университетының — тарих-филология, Удмурт педагогия институтының тарих факультетларын тәмамлый (1956, 1961). 1956–1961 елларда Башкортстанның Тәтешле районы Югары Кодаш, Иске Күрдем мәктәпләрендә укытучы, директор урынбасары булып эшли. 1961–1964 елларда Казан педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы каршында аспирантурада укый. 1964 елдан Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының татар әдәбиятын укыту методикасы кабинеты методисты, 1971 елдан — РФ Мәгариф министрлыгы каршындагы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Татарстан филиалы, 1996 елдан ТР Фәннәр академиясе Тарих институтының Милли мәгариф теориясе һәм тарихи үзәге өлкән фәнни хезмәткәре булып эшли.



Ф.Ф.Исламов

Фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлешләрен урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы, интернациональ тәрбия, татар әдәбиятының Идел буе һәм Урал яны халыклары әдәбиятлары белән багланышлары, татар язучыларының педагогик идеяләре, әдәби төбәкне өйрәнү мәсьәләләре тәшкил итә. Каюм Насыйригa багышланган мәкаләләрендә галимнең күпкырлы, аерым алганда педагогика, милләтара дуслык хисләре тәрбияләү өлкәсендәге эшчәнлеген киң яктырта, әлеге җәһәттә ул: «Туган халкының матур киләчәгенә ышанган Каюм Насыйри Россиягә, рус халкына ихтирам белән карады, халыкларыбыз арасында дуслык, туганлык тойгылары тәрбияләүгә зур көч куйды, татар халкын рус әдәбияты үрнәкләре белән таныштырды», — дип яза. Ф.Исламов шулай ук галимнең укыту эшләре Россия җирлегендә һәм рус халкының алдынгы педагогик фикерләре нигезендә үсәргә тиеш дигән карашларын ассызыклый. К.Насыйриның туган җиргә, туган илгә мәхәббәт тәрбияләүгә

аеруча игътибар итүе турында сүз алып барып: «Ул Ватан төшенчәсенә татар халкы яшәгән географик урынны гына түгел, Россиянең бөтен халыклары яшәгән территорияне кертте. Үзен горур рәвештә Россия гражданины дип исәпләде», — дип икърар итә.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар әдәбиятын укытканда интернациональ тәрбия (5–8 нче класслар). Казан, 1968; Туган илне сөю хисе: К.Насыйриның тууына 150 ел тулу алдыннан // Социалистик Татарстан. 1975. 7 февраль; Әдәбият дәресләрендә туган якны өйрәнү материалларыннан файдалану. Казан, 1983; Халыклар дуслыгы кыңгыраучысы // Татарстан хәбәрләре. 1995. 8 февраль; Татар әдәбиятын укытканда милләтара бәйләнеш (Идел буе һәм Урал яны халыклары үрнәгендә). Казан, 2000; Каюм Насыйриның педагогик эшчәнлеге һәм педагогик каршлары // Национальная школа и актуальные проблемы обучения: сборник статей. Казань, 2001.

Әд.: Гарифьянова Р., Җәләлиев Ш. Игелекле хезмәт кешесе // Мәгариф. 1992. № 9.

Р.Ф.Исламов.

ИСТӘЛЕКЛӘР (хатирәләр), әдәбият жанры (мемуар әдәбият); узгандагы хәтердә сакланган вакыйгаларга яки фактларга әйләнеп кайту, үткәннәрне образлар, күренешләр яки берәр кеше белән вербаль (телдән, сөйләм рәвешендә) аралашуларны колачлаган күзаллаулар рәвешендә күңелдә, уйда кабатлау, яңарту.

Каюм Насыйриның тормыш юлы, эшчәнлеге турында тулы манзара тудыру юлында истәлекләр белән якыннан танышуның әһәмияте зур, алар бу очракта мәгълүм дәрәҗәдә чыганак буларак өйрәнелә. Махсус җыентык рәвешендә нәшер ителмәсәләр дә, К.Насыйри хакындагы истәлекләр аерым басмаларда урын ала. Алар Ризаэтдин *Фәхретдин* тарафыннан чыгарылган «*Шура*» журналында (11 истәлек), «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 ел 15 февраль санында һәм «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга» җыентыгында (1926) (1 әр истәлек), 1940 һәм 1945 елларда «Совет әдәбияты» журналында (2 истәлек), «Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)» җыентыгында (1948) (8 истәлек), кайберләре (6 истәлек) кабатлап, Фатыйма *Ибраһимова* туплаган хәлдә Галимҗан Гыйльманов әзерләп бастырган «Әдәби мирас» сериясенең 3 нче китабында (1996), Фатыйма Ибраһимованың «Фәнни гомерем мизгелләре» китабында (2012) барысы да (яңа ачыкланганнары өстәлеп, 20 истәлек), тәүге тапкыр бергә җыйналган рәвештә Рәмил *Исламов* тарафыннан төзелеп, 2017 елда нәшер ителгән «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык» басмасында урнаштырыла.

Истәлекләрнең күпчелеге беренче тапкыр «Шура» журналында басыла. Журналның 1912 ел 21 санында Ризаэтдин Фәхретдиннең «Габделкаюм Насыйри» исемле мәкаләсендә Сөләйман *Аитовның*, Әхмәтһади *Максудиның* һәм Фатих *Кәриминең* истәлекләре китерелә. С.Аитов яшь вакытында К.Насыйридан беркадәр сабак алуы, аны үз өендә яшәтеп, шунда үз улы һәм Троицк шәһәренең танылган сәүдәгәре, иганәче Габделвәли Яушев (1840–1906) улы янына алты фәкыйрь бала кушып укыттыруы, аның балаларны әдәпле итеп тәрбия кылуы хакында искә ала, галимне үзенең остазы дип атый. Әхмәтһади Максуди исә истәлегендә Казанга кайтуында Кырымның Бакчасарай шәһәрендәге «Зынҗырлы» мәдрәсәсенең рус теле мө-

галлиме Исмәгыйль Лиманов йомышы буенча К.Насыйри янына барып, аның рәсемен, мөгаллим юллаган сорауларга җавапларын күндерүен соравы, галимнең тышкы кыяфәтен (киемнәре — камчат бүрек, тукымадан (бикасап) тегелгән казаки, аягында — оеклар) күздән кичерүе, үтенечләрне кире кагуы турында хәбәр итә. Фатих Кәрими Ризаэтдин Фәхретдингә 1896 елда Истанбулдан — Петербургка, аннан Мәскәү аша Казанга килеп, Екатерининский урамының сул ягындагы бер йортның ишегалдындагы флигельдә — кечерәк бер агач йортта К.Насыйри белән очрашуы хатирәсен язып бирә. Ул галимнең Ә.Максуди күргәндәгечә киемнәрдә һәм шөгыльдә (сабак укыту) булуын, өстәл янында стенада чабата эленеп торуның сәбәбен аңлап бетермәвен, рәсемен сорагач, элекке сәбәп (рәсемгә төшмәве) китерелеп, буш кул, әмма югары кәеф белән чыгуын («Аны күрүемездән бик мәмнүн калдык. Чөнки фәкыйрь вә мәскәнәт [мескенлек] эчендә торып та, заманасына вә мохитенә күрә шулкадәр зур әдәби вә гыйльми хезмәт итә алуның мөмкинлеген күрү безнең күңелләрдә куәт вә истикъбаль (киләчәк) өчен өмид арттырды») искә ала.

Нуретдин *Ишаевның* «Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләр»ендә аның, 1898 елның маенда Казанга барып төшкәч тә, остазы Фәйзерахман хәзрәт белән Екатерининский урамында, сул якта урнашкан Сөләйман Аитов йорты биләмәсендәге кечерәк бер агач йортта галим белән очрашуы бәян ителә. Алар өйгә ул чәй эчеп утырган чакта килеп керәләр. Автор башта йорт эчен («Түрдәрәк, урталыкта, борынгы мәдрәсәләрдә тотыла торган тәбәнәк өстәл, өстенә бернәрсә дә җәймәгән. Өстәлдә ике касә вә бер шакмак шикәр, бер телем арыш икмәге, самавар бар. Ләкин самавары җизме, бакырмы — беленерлек түгел, кап-кара керләнгән»), К.Насыйриның тышкы кыяфәтен («Шул өстәл янында Бәләбәй өязе Бурангол башкорты рәвешендә киң якалы киндер күлмәк кигән, якасында изү бау (ялау), башында балан кагы кеби түбәтәй, аягын бөкләп утырган Габделкаюм әфәнде чәй эчәдер. Бер ягында ачылып куелган китап бар») сурәтләп, бераз әсәрләрен алырга ниятләрен белдереп, соңында аның зарларына (китапларны үзе бастырырга көче җитмәве, аларны нәшер итүнең кыйммәткә төшүе, таратуның авырлашуы сәбәпле наширләрнең илтифат кылмавы, татарларның китап уку белән мавыкмавы, Казан халкында хатын-кыз бозыклыгы, кием-салымда кыяфәт алмаштырулар, Казан халкының (аны) бәяләп бетермәве) күчә.

Һади *Тәһири* «Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләр» язмасында галимнең үзе белән шәхсән таныш булмавын һәм аралаша алмавын искәртә, истәлектә башлыча сүз аның туган-тумачалары хакында бара (Һ.Тәһири К.Насыйриның кулъязмалары аның төпчек энесе Габделкави улы Габдерахман карамагында сакланырга тиеш, дип исәпли; ул аның кулъязмаларын һәм басылган әсәрләрен абыйсы Габделхәй улы Габделмән кулында күрүен әйтә).

Галимҗан *Акчурин* «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат» хатирәсендә В.В.*Радловның* К.Насыйрины, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Шаһбазгәрәй *Әхмәровны* (1853–1900) һәм педагог, ветеринар Ибраһим *Терегуловны* (1852–1921) *Казан татар укытучылар мәктәбенә* укыту эшенә чакыруы, әлеге өч шәхеснең 7–8 ел үзара аралашуы турында хәбәр итә, соңгы икесе «Шура» журналы аша галим турындагы истәлекләре белән уртаклашкан очракта, «Габделкаюм әфән-

денең дә тәрҗемәи хәле бераз тулырак чыгар иде», дип белдерә.

Мөхәммәткамал *Мозаффарның* «Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр»ендә аның, 1896 елда Казанга килгәч, К.Насыйри белән озак вакыт сөйләшеп утыруы ассызыклана, күргән-ишеткәннәре махсус дәфтәргә языла; кызганычка каршы, дәфтәр «мәгълүм вакыйгада» аңардан алынып, кире кайтарылмый, шул сәбәпле, автор үзе тануынча, әлеге очрашу турында тәфсилләп сөйли алмый, фәкать аның кояш нуры һәм эсселеге кими баруы хакындагы фикерләрен искә төшерә һәм берничә сүз белән тышкы кыяфәтен («Өстендә бикасап тышлы кыскарак тун вә аягында бәйләгән оек иде), йорт эченең күренешен («Идән чүпле вә җыйнаксыз иде. Диварына асып куйган ике гадәд (сан) шәһадәтнамәме, нинди язудыр бар иде. Хәтеремдә калдыгына күрә, бу язулар дарелфөнүн (университет) идарәсе тарафыннан вирелмеш иде.Үзе дарелфөнүндә хезмәттә идекене вә анда ифрат дәрәҗәдә китап күплегене сөйләде») тасвирлый, хезмәтче малайның яман телле булуын һәм һәр кушылган йомышка каршы сүз әйтүен билгеләп уза, шәхсән үзендә К.Насыйриның ике хаты һәм бер китабына нисбәтле хисап язуы саклануы хакында белдерә.

Насретдин *әл-Хуҗашиның* мәгърифәтче галим белән булган әңгәмәсе турындагы истәлекнең «Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри белән мосахәбә (Хатирә дәфтәремнән)» дип аталышында ук аның башка истәлекләрдән аермасы — вакыйгадан соң кичекмәстән теркәлүе чагыла, шул рәвешле анахронизмнан азат булуы белән хатирәнең чыганак сыйфатындагы әһәмияте бермә-бер арта, автор аны, «Шура» журналы үтенеченә җавап рәвешендә махсус дәфтәреннән күчереп, әлеге басманың редакциясенә юллый. Насретдин хәзрәт башта, төрле кешеләрнең гаделсез фикерләре йогынтысында, галимгә һәм аның хезмәтләренә карата тискәре, хәтта нәфрәтле карашта булуы, тора-бара «соң елларда шәкертләр арасында мәдрәсәдә укылган дәрес, фән вә китаплардан ризасызлык» таралуы нәтиҗәсендә, «мәдрәсәләрдә мөтәдавил [кулдан-кулга йөртелүче] китапларның эшкә, фәннәре тәгълимгә [өйрәтүгә] яраксызлыклары аңлашылгач», «Каюм Насыйри хәзрәтләренең китаплары да мәдрәсәгә үтеп кереп, сөелеп укыла башлагач» аңа карата мөнәсәбәте тамырдан үзгәреп, аны «гаибәнә сурәттә чын күңелдән сөя» башлавы һәм аны күрергә теләве хакында яза. Истәлектә киләчәктә публицист буларак танылачак Фуад Туктаров (1882–1934) һәм булачак драматург, педагог Габдерәүф Ниязбаев (1881–1934) катнашында 1902 елның 9 гыйнварында Каюм Насыйри белән булган әңгәмә вакытындагы йортның эчке күренеше («Ике зур бүлмәдән гыйбарәт бу өйнең алгы бүлмәсендә икенче бала керосин машинкасы илә аш пешереп тора. Эчке бүлмәнең сул касагыннан сузып урам як стенасына йирдән аршин ярым юкарыда беләк калынлыгында бер агач беркетелгән. Ишекнең сул ягында бер шкаф — эчендә китаплар, стенага бер пычкы эленгән, йирдә балта, өтерге, наструк вә башка кораллар, агач кисентеләре, кәгазь парчалары ята. Гомумән, өйнең эче тәмиз түгел [чиста түгел], бәлки, артык дәрәҗәдә нәзафәтсез [пакьсез] иде. Өстәл артында каралып беткән диванга утырып, сул яңагын тәмам өстәлгә тигезгән, каләменең яза торган очына күзен якын китергән хәлдә, күркә каләм илә язып торган камчат бүрекле бер шәйхе фани [бик картайган кеше] күрдек вә сәлам бирдек») тасвирлана, күтәрелгән төрле мәсьәләләр (галимнең ялгыз яшәве сәбәпләре, Ка-

зан университетына карата мөнәсәбәте, иҗаттан ял итеп алганда төрле кораллар белән нәрсәләрдер ясавы, нинди хезмәт өстендә эшләве һ.б.) бәян ителә, К.Насыйриның күзләре начар күрүе һәм колакларының начар ишетүе искәртелә, аның «Аллаһ мине китап язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру Аның хөкеменә каршылык булыр дәюп куркам» дигән сүзләренең көчле тәэсир итүе ассызыклана. К.Насыйри кунакларга яңарак төгәлләнгән 750 битлек кулъязма хезмәтен (ул чакта әле галим аны исемләмәгән була) күрсәтә, 2015 елда кулъязма «*Мифтах әл-Корьән*» исеме белән 2 томлык факсимиль басмада чыга.

Мөхәммәтнәҗип *Түнтәринең* «Габделкаюм Насыйри хакында хатирәтем» дигән истәлегендә К.Насыйри белән берничә тапкыр очрашуында аның исереклек таралуына борчылып язган әсәрен күрсәтүе, мәдрәсәләрнең шәкертләргә тиешле әхлак тәрбиясе биреп җиткермәвеннән зарлануы, үзе белән хат алышуы турында искә алына.

Гарифулла бине Гали *Чокрый* К.Насыйри белән тәүге мәртәбә 1879 елда, 18 яшендә Казанга әтисен (шагыйрь Гали Чокрыйны (1826–1889)) өченче хаҗ сәфәренә озата килгәндә, шәһәрдәге мәдрәсәләрне күреп-танышып чыкканнан соң очраша; очрашулар ул Казанда мәдрәсәдә укырга калгач та кабатлана. Беренче тапкыр килгәндә аталы-уллы Мөхәммәтгали һәм Гарифулла Насыйриның хуркур (кальян) суырып утырган чагына тап булалар, кайбер очрашуларда Гарифулла аның курай уйнаган вакытына туры килә. Аның истәлекләренең күләме зур түгел («Шура», 1913, №5), аларның үзенчәлеге — галимнең башлыча татар теленә, белем алуга, милләтләргә карата хөрмәтле мөнәсәбәте, татарларның кимчелекләренә борчылуы яктыртылу, бүлмәсендәге әсбап-кораллар тасвирлану («Чөйгә эленгән бер эскрипкә вә балалайкасы да бар иде. Ишек төбендә бәләкәй генә чары, таяк һәм шар кыра торган ыстанук-кораллары бар иде»). Әлеге хатирәләрдә шул елларда К.Насыйриның Госманов мәчетеннән (Кызыл мәчет, Солтанов мәчете, 8 нче мәчет) берничә йорт аша гына яшәве, «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» хезмәтен яза башлавы, янгын вакытында күп кенә кулъязмаларының юкка чыгуыннан, календарьларының берсе урланып, чит кеше исеменнән чыгарылуыннан зарлануы, Гарифулла Чокрыйның биш ел дәвамында (1879–1884) Казанда мәдрәсәдә укыган чорда туган ягына (Уфа губернасы Бөре өязе Иске Чокыр авылына) кайтып йөргәндә аның әсәрләрен үзе белән алып кайтып, сатып бирүе хакында телгә алына.

Мөхәммәтхәнәфи *Мозаффарның* өч өлештән торган «Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында» дип аталган хатирәләре — хәзерге вакытта мәгълүм истәлекләр арасында иң күләмлесе. Анда әтисе, ихтимал, Татарстанның хәзерге Кукмара районына кергән Шепшеңәр авылы кешесе Мөхәммәтҗанның Шиһабетдин Мәрҗани укыткан «Мәдрәсәи Мәрҗания» шәкерте булган заманда күп тапкырлар Каюм Насыйри белән аралашуы, аңарда аның язмаларыннан («Әмсале Коръән», «Әмсале хәдия», «Хикәят вә ләтаиф», «Төрек вә татар тарихы») күчерелгән 44 битлек кулъязма саклануы, әтисенең сөйләвеннән — галимнең тышкы кыяфәте («Аның (Насыйриның) үз сүзенә караганда, уң күзенә кызамык илә ак төшкән вә сул күзе тумыштан сукыр булган. Уң күзе яхшы күрә иде. Ләкин даим күк күзлек истигъмаль кылды. Аягында сауырыйлы читек-кәвеш, өстендә ак көмеш төймәле казаки. Борынгы әйләнмә якасыз зәңгәр постау чикмән. Зәң-

гәр постау чалбары кәвеш йөзенә төшеп тора иде. Башында бер карыш киңлегендә камчат бүрек, кулында җәйләрдә зонтик, кышын кыска таяк тота. Тамак толып вә яхшы туннары һәм бар иде»), хатын-кызларга карата салкын мөнәсәбәте, кайбер кешеләр белән аралашуда бик үк ачылып бетмәве, ике ай (сентябрь-октябрь) дәвамында «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»ны күчереп бирү хисабына көнгә өч сәгать исәбеннән Насыйридан рус теле өйрәнүе; үзе исеменнән мәгърифәтченең татар һәм рус телләренә мөнәсәбәте, В.В.Радлов белән фикер каршылыклары аркасында татар балалары өчен башлангыч рус-татар мәктәбендә укытудан китүе сәбәпләре һ.б. бәян ителә.

Габдулла бине Тажетдин *әл-Кәчимиригә* галим белән яшүсмер елларыннан башлап күп тапкырлар очрашырга насыйп була. 1876–1877 елларда ул, Күл буе мәдрәсәсе шәкерте, К.Насыйри «Закир хәзрәт мәхәлләсе булган Балан Шаһи йортында, Приходский училишчедә учитель булып торганда», русча уку зур гаеп булып саналган чорда, берничә шәкерт белән бергә кичләрен аңардан рус теле дәресләре алырга йөри. Аның «Габделкаюм ән-Насыйри» хатирәсе («Шура», 1913, №10) башлыча К.Насыйриның тышкы кыяфәтен («Габделкаюм ән-Насыйри әфәнде урта буйлы, зур башлы булып, чәчен җитүрәк йөртә иде. Борын вә авыз килешле, төсе ак түгел, бәлки богдай төслерәк, йөзе ачык түгел, караңгырак иде. Күзләре зәгыйфь булудан язуны күзенә бик якын китереп карый иде. Мыекны җитүрәк йөртә иде. Сакалы сирәк булып, артык озын йибәрми иде. Йөрүе әкрен, алдына карап турырак булып йөри иде. Киемнәре артык кыска вә озын да түгел иде. Хәлен белгән адәмнәр элек русча укып йөргән вакытларында яврупачарак та киенеп йөргән, диләр») һәм холкын («Ул вакыт Казан муллалары арасында вә күп адәмнәр каршында игътибары юк иде», «Үзен Казан халкы күбесе яратмаган кеби, үзе дә Казан халкының күбесен яратмый иде», «Мәҗлесләрдә булмый, булганда да сүз сөйләми, тик утыра. Сөйләгәндә кычкырмый, ашыкмый сөйләшә вә күп сүзле түгел иде. Мактанмый вә үзен югары тотмый иде. Янына кереп, берәүләр: «Г[абделкаюм] абзый, безгә хәзер русча лөгать китабы яки тыйб (медицина) китабы, йә җәгърәфия кирәк» — дисәләр, шуларны игътибарга алып, вөҗүдкә чыгарырга тырыша иде») җентекләп тасвирлавы белән үзенчәлекле. Шәкертлек чагында галимнән рус теле дәресләре алган чордан соң егерме ике ел узгач, әл-Кәчимири аның белән 1899 елның июнендә Казанда, ул яшәгән Бәдигъ мөәзин (туганы Мөхәммәтбәдигъ) фатирында очраша, аның яшәү шартларының начар булуын, тамагын ашханәдә туйдыруын, китапларын шәкертләр һәм приказчиклар гына яратып укуыннан, татарларның укуга игътибар бирмәвеннән, китаплар бастыруның кыйммәткә төшүеннән зарлануларын, мөмкин булганча гарәп һәм фарсы алынмаларыннан арынып, хезмәтләрен «төркичә» язуын, «Җыен» дип аталган сәхифә чыгарып, анда муллалар, байлар, хезмәткәрләр, икмәкче-күмәчеләр, йорт-урам себерүчеләрнең яшерен эшләрен тәнкыйтьләвен икърар итә һәм мисалга Насыйриның дүрт юллыгын китерә:

Бардыр бер нәугъ (төр) халык, сән аны чухур (мещан) ата,

Эше юктыр, ашы юктыр, торганы — суган сата.

Ошбу нәугъ кешеләрнең урныдыр Печән базар,

Бу кешеләргә иярсә, суфи һәм мулла азар.

Мөхетдин *Корбангалиевнең* «Каюм Насыйри турында истәлекләр»е беренче мәртәбә — «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 ел 15 февраль санында, шулай ук беркадәр үзгәртүләр белән 1926 елда Казанда нәшер ителгән «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга» басмасында дөнья күрә. Автор аларда К.Насыйри белән беренче мәртәбә 1890 елның язында (*Казан татар укытучылар мәктәбендә* бер ел укыгач) күрешүе һәм аннан соңгы очрашулары хакында бәян итә.17 яшьлек егетнең аңарчы галимне олпат кыяфәтле зат итеп күзаллавы турында: «Казанда бер ел торып үзебезнең зур кешеләребез, инспекторларыбызның зур һәм матур җыештырылган фатирларын күреп өйрәнгәнгә, Каюм абзыйны алардан да яхшырак тора торгандыр, дип уйлап кергән идем», — дип яза, тәүге тапкыр очрашкач та, чынбарлыкның уйлары белән туры килмәвен («фатиры җыештырылмаган, үзе бик юаш») икърарлый, әлеге очрашуларның һәм Каюм Насыйри хезмәтләренең сайлаган һөнәренә гаять уңай һәм көчле йогынты ясавына басым ясый («Һәркайчан, һәр мәҗлестә тел һәм имля турында Каюм абзый юлында бардым»), хатирәләрен галимгә мөрәҗәгать итү рәвешендә: «Менә Насыйри абзый, синең васыять итеп калдырган юлыңда мин утыз ел эшләдем. Минем кебек синең юлыңда эшләүчеләр бик күп булдылар», — дип тәмамлый.

Әхмәт Хөсәеновның («Каюм Насыйри миңа абый тиешле кеше иде, аның атасы минем бабам (атамның атасы) белән бертуган булган» дип тануынча, ул — галимнең югарыда Габдулла әл-Кәчимири исәлекләрендә телгә алынган туганы Бәдигъ мөәзиннең (Мөхәммәтбәдигъның) улы) «Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр»е «Совет әдәбияты» журналының 1940 ел 7 санында урын ала. Әлеге хатирәләргә төгәллек хас (авторның еш кына «хәтерлим» сүзен куллануы да шуңа ишарә), аларда югарыда китерелгән истәлекләргә аваздаш рәвештә дияр-лек К.Насыйриның тышкы кыяфәте («Каюм абзыйның ул еллардагы кыяфәтен мин түбәндәгечә хәтерлим: ул уртача буйдагы, кара чырайлы, очлырак һәм чал кереп килә торган кечерәк кенә сакаллы, бер күзе сукырайган, ябык һәм чандыр кеше иде. Өстендә, һәр вакытта диярлек, казаки, башында кара хәтфә кәләпүш, аягында читек, чалбар балакларын читек эченә тыгып кигән була иде. Башта аның бер күзе сукыр булса, соңыннан ул ике күзсез калды. Шуңа күрә тотынып чыгар өчен аның квартирасының алдагы бүлмәсенә кадәр озын итеп киртә кагылган иде» (бу киртә хакында югарыдарак искә алынган Насретдин әл-Хуҗаши хатирәләрендә дә әйтелә)), аның торагының эчке күренеше («Каюм Насыйриның квартирасы эче үтә гади иде. Аның стеналарына төрле географик карталар асылынган бүлмәсендә бик гади генә өстәл, берничә утыргыч, зур бер шкаф тора. Шкафның өске каты төрле язма һәм басма китаплар белән, аскы каты төрле клещи [клəщə], чүкеч, тимер чыбыклар, катыргылар, әйберләр кайната торган калайлар, савытлар белән тулган. Шкаф янында тагын кечкенә генә бер өстәл тора: анда рус, татар, гарәп, фарси телендәге китаплар, журналлар, газеталар, глобуслар, картиналар, микроскоп, силомер һәм башкалар тәртипсез чәчелеп яталар. Тәрәзә төбендә спирт лампасы, өчаяк, агач тартма, ачуташ, купорос һәм башка әллә нинди, төрле-төрле ташлар салынган пакетлар ята иде»), галимнең шөгыльләре (хезмәтләр язуы, үзе калайдан ясаган калыпта шәмнәр коюы), аш-су, ризыклар (пылау, шәкерт салмасы, кулла-

ма) әзерләве, календарьлар нәшер итүе, табигатькә чыккач төрле шифалы үләннәр җыюы, авторны укырга-язарга өйрәтүе, аның физик хәрәкәтләр ясауны һәм йөзүне якын итүе, вафатына берничә ай калгач чыккан янгын вакытында сукыр хәлендә дә күңеле төшмәве тасвирлана. Әхмәт Хөсәенов истәлекләрендә К.Насыйриның рус, татар, гарәп, фарсы, хәтта немец һәм француз телләрен өйрәнүе, вафатыннан соң аның яшәгән җирендә немец һәм француз китаплары табылуы, жәназасында халыкның аз булуы, туганы Габделмән Казанскийның аның барлык китапларын һәм башка нәрсәләрен җыеп алып китүе, ләкин аларны тиешенчә сакламавы, китапларының һәм әсбапларының таралып-югалып бетүе хакында хәбәр итә.

Миргазиз *Укмасыйның* «Каюм абзый Насыйри» дип аталган истәлегендә К.Насыйри йогынтысына тартылуы галимнең авыл тегермәне йортының тәрәзә төбендә яткан китабына тап булудан башлануы, китапны эти-әнисенең укуы, соңрак аның авыл халкы арасында кулдан-кулга йөрүе, 1898 елда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлагач, Каюм Насыйриның календарьлары һәм башка әсәрләре белән танышуы турында әйтелә һәм 1901 елда 17 яшьлек Укмасиның мәгърифәтче галим белән очрашуы (Насыйриның аны шәхсән каршы алуы, әңгәмә вакытында нәселе белән кызыксынуы, Татар укытучылар мәктәбендә укырга, рус телен һәм төрле фәннәрне өйрәнергә өндәве һ.б.) тәфсилле бәян ителә. Истәлектә, башка хатирәләргә дә хас булганча, мәгърифәтченең килеш-килбәте («Аның аягында читек, яхшук кыска чалбар, өстендә озын ак күлмәк, аны эченә тыкмаган, аның өстеннән җиңсез камзул кигән, аны төймәләмәгән, шулай ук күлмәк якасы да төймәләнмәгән иде. Башында яхшы хәтфә кәләпүш, аны яхшук артка җибәргән, яше зур булса да күңеле шат, ләкин бөтен күңеле белән эшкә чумган иде»), торагының («Каюм Насыйри квартирасы ерак түгел, шул ук Тукай урамында, хәтеремдә ялгыш калмаса, чаттан икенче яки өченче йортның ишегалдында иде») эчке күренеше («Ишек кергәч тә верстак, ләгән, комган, стенада элгән сөлге, шунда ук кечерәк кенә бер сәке, бер табуретка, верстак астында йомычкалар. Бу бүлмә кечкенә генә иде...Каюм абзый мине түр якка алып чыкты, анда гади өстәл, шкаф һәм бер як стенада өелгән китаплар иде. Стенада пыялага язылган ике шамаил, ләкин аларга нәрсә язылганын мин хәзер хәтерләмим») күздән кичерелә; автор «ул вакытта татарларда дини фанатизм бик көчле һәм аң түбән булганга» Каюм Насыйрига тиешле бәя бирелмәвенә борчылуын белдерә, аның үз-үзен тотышыннан, ярдәмчеллегеннән, тирән фикерләреннән алган кичерешләре белән уртаклаша.

Вафа *Бәхтияровның* 1945 елның 30 июлендә язылган «Каюм абзый Насыйри турында кечек бер истәлек» хатирәсе Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының *Язма мирас үзәгендә* саклана, шуннан алынып, беренче тапкыр Рәмил Исламов тарафыннан төзелеп, 2017 елда «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык» басмасында дөнья күрә. Ул ике өлештән тора. Беренче өлештә атналык «Тавыш» газетасы (1907 елның 23 апреле — 5 июне) наширләренең һәм мөхәррирләренең берсе Хөсәен Әбүзәровка (?–1917), К.Насыйри тарафыннан төзелеп, беренче мәртәбә 1878 елда басылган «Русча-татарча сүзлек» кирәклеге сәбәпле, 1901 елның сентябре ахырында галим белән булган очрашу хати-

рәсе бәян ителә. Шул чакта Екатерининский урамындагы ул яшәгән йортның барлык истәлекләр арасында иң тулы эчке тасвирламасы бирелә («Без кергәндә Каюм абзый тәбәнәк кенә, дүрт почмаклы бер өстәлгә каршы идәнгә утырган иде. Астында калын гына, уртага бөкләгән көрпә иде. Шул калын көрпә өстенә аягын бөкләп утырган, өстендә җиңсез чуар камзул, башында фәс тә түгел, кәләпүш тә түгел, тирән генә бернәрсә иде. Өстәл өстендә зур гына берничә китаплар күренә. Шул китаплар арасында зур гына бер лампа, лампаның кәгазь абажуры янып, каралып, тузанланып беткән. Лампаның пыяласы сөртелмәгән, корымга баткан хәлдә күренә иде. Лампа янында зур гына кара савыты; кара савыты янында берничә каурый каләм, берничә ручка күренә. Ишектән кергәч тә сул якта стенага эленгән берничә пычкы, берничәләп өтерге күренә. Уңъяк стенада кадакларга эленгән төрле күләмдә үлән көлтәләре күренә иде. Ишеккә каршы булган стенада озын, киң, прастуй кызыл башлы авыл сөлгеләре эленгән. Шул авыл сөлгеләре арасында карга оясына охшашлы зур гына компас, бер бүрек һәм бер тышкы кием эленгән. Идәндә стена буенда һәм өйнең почмакларында тәртипсез рәвештә төрле күләмдә төрле буллар белән бәйләнгән китаплар өелеп ята иде. Өйнең капкага карап торган тәрәзә янында тагын бер тәбәнәк өстәл. Шул өстәл өстендә каралып беткән бер самаур, берничә пар чынаяк, берничә аш тәлинкәсе, бер кәстрүл һәм башка төрле нәрсәләр күренә иде. Өйнең почмакларында үрмәкүчләрнең иркен рәвештә яшәгәннәре, төрле күләмдә үрмәкүч оялары, үрмәкүч пәрдәләре күренә. Өйнең түшәме, стенасы гомер буе юылмаган, кап-кара булып күренә иде. Өйнең идәне юылмаган, рәтләп себерелмәгән, тузан-туфрак, төрле күләм кәгазь кисәкләре һәм башка төрле чүпләр белән тулган. Ишектән кергәч, сул почмакка якын бер карават сымак нәрсә күренә. Карават тузган хәлдә күренә иде»), мәгърифәтче галимнең килүчеләргә (Хөсәен Әбүзәровка һәм Вафа Бәхтияровка) «Русча-татарча сүзлек», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият», «Ләһҗәи татари» китапларын сатып бирүе хакында искә алына. Икенче өлештә («Каюм абзыйның җеназасы») аны җирләү хакында бәян ителә һәм күренекле шәхесләрнең — күп кенә татар зыялыларының әлеге вакыйгада катнашмаулары мисалында аңа карата мөнәсәбәтләре бәяләнә.

Гыйбадулла *Төхфәтуллин*, Талип *Гайсин*, Гыйльман *Ногманов*, Мәсхәпҗамал *Ибәтуллина* һәм Гатаулла *Дусаев* истәлекләре, 1945 елның февралендә Югары Шырдан авылында К.Насыйриның 120 еллык юбилеена әзерлек кысаларында фольклорчы галим Хәмит *Ярми* тарафыннан язып алынып, 1948 елда нәшер ителгән «Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)» җыентыгында урнаштырыла. Аларда К.Насыйриның авылга кайтып йөрүе, кайткан вакытларында балалар, авыл халкы белән аралашуы (балаларга — акча һәм конфетлар, халыкка китаплар өләшүе, укырга, белемле булырга чакыруы, мәктәп салдыруы), холкы (һәрвакыт үз эше-хезмәтләре турында уйланып йөрүе, аз сүзлелеге, тыйнаклыгы, гадилеге), шөгыльләре хакында сөйләнелә.

Габделбарый *Насыйровның* (1881 елда туган) һәм Зыя *Бәхтияровның* истәлекләре шулай ук 1945 елда, К.Насыйриның 120 еллык юбилеена әзерлек кысаларында, язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт *Гали* тарафыннан язып алынып, 1948 елда дөнья күргән гыйльми сессия материаллары җыен-

тыгында басыла. Г.Насыйров, үзе язганча, — әнисе ягыннан галимнең туганы, ул аны беренче мәртәбә 12 яшендә әтисенең бертуган сеңлесе Хөснижамал абыстай Шырданга К.Насыйриның энесе Габделкави хәзрәт янына кунакка алып баргач күрә; аңарчы, әнисеннән ишетеп, беркадәр аның хакында хәбәрдар була. Әлеге хатирә аның авторы мәгърифәтченең йөз-кыяфәтен Байназар Әлминов ясаган рәсемдәгегә шактый охшаш булуны раслау белән дә мөһим. Яңа Смәил авылының (хәзер Киров өлкәсенең Малмыж районына керә) элекке мулласы З.Бәхтияров К.Насыйри белән тәүге мәртәбә 1898 елда, «Горрәи даими» дип аталган өстәл календаре һәм астрономия буенча «Рисаләте робгы мөҗәйяб мәгаль каванине хисап» китабын язганда, киңәш сорап барып күрешә, соңрак та галим янына килгәләп йөри; аның төрле фәннәр буенча тирән белемле булуын, килгән саен янында һәрвакыт кешеләр булуны, аларның күбрәк медицинага кагылышлы, шулай ук авырулардан дәвалану юллары һәм чаралары хакында киңәшләр соравын ассызыклый.

Хатип *Алишев* 1945 елның гыйнвары ахырында «Кызыл Татарстан» газетасында К.Насыйриның булачак юбилее турындагы хәбәрне укый һәм, 1884–1895 елларда аның белән булган әңгәмәләренә бәйле хатирәләре нигезендә, шул ук елның 18 июнендә истәлек яза. Ул 1948 елда дөнья күргән гыйльми сессия материаллары җыентыгында урын ала. Алар башлыча мәгариф, халыкны агарту, төрле фәннәрне өйрәнүнең фарызлыгы хакында сөйләшәләр. Бу әңгәмәләр хатирә авторына көчле йогынты ясый, шул сәбәпле ул үз истәлеген, галимне вакытында тиешенчә бәяли алмауга ачынып, «Менә хәзер күзләребез ачыла төшкәч, Насыйриның зурлыгы күренә башлады. Дөрестән дә ул олы йолдыз икән», — дип тәмамлый.

Истәлекләрдә К.Насыйри белән төрле очрашуларда хатирә авторларында туган тәэсирләр, галим яшәгән мохит һәм аның тормыш итү рәвеше, холкы, үз-үзен тотышы тасвирлану, педагогик, фәнни карашлары, дөньяви фикерләре, милләтпәрвәрлек хисләре бәян ителү аларның чыганак буларак әһәмиятен тагын да арттыра.

Әд.: Акчурин Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат // Шура. 1912. № 23; Әл-Кәчимири. Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. 1913. №10; Әл-Хуҗаши Н. Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри белән мосахәбә (Хатирә дәфтәремнән) // Шура. 1912. №24; Ибраһимова Ф.И. Каюм Насыйри турында истәлекләр // Әдәби мирас. Казан, 1996. 3 нче кит.; шул ук. Фәнни гомерем мизгелләре: Мәкаләләр, истәлекләр, иҗат портретлары. Казан, 2012; Ишаев Н. Каюм Насыйри хакында истәлекләр // Шура. 1912. №22; Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр // Совет әдәбияты. 1940. №7; Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Исламов Р.Ф. Казан, 2017; Корбангалиев М. Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926; Мозаффар Мөхәммәткамал. Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. №23; Мозаффар Мөхәммәтхәнәфи. Габделкаюм әфәнде хакында // Шура. 1913. № 8; Таһири Һ. Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. №23; Түнтәри М. Габделкаюм Насыйри хакында хатирәтем // Шура. 1913. №3; Укмаси М. Каюм абзый Насыйри // Совет әдәбияты. 1945. №2; Фәхретдин Р. Габделкаюм Насыйри // Шура. 1912. №21;

Чокрый Г. Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. 1913. №5.

И.Х.Хәлиуллин.

«ИСТЫЙЛАХӘ́ТЕ ҖӘГЪРӘФИЯ́» («География терминнары»), география төшенчәләре китабы. География фәне белән башлап шөгыльләнүчеләр өчен Каюм Насыйри трафыннан языла һәм 1890 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә.

К.Насыйри китапның сүз башында аның кирәклеген болай аңлата: «Заты вә җисеме үзенең ханәсендә диваны өстендә мөтәкяә [таянып] бу фән китапларын карап яткан хәлдә, гакылы вә зиһене белән әтрафы галәмгә сәйр вә сәяхәт кылып, никадәр гыйлем әҗмәле [күркәм гыйлем] хасыйл итәр ки, бөтен гомер сәяхында йөргән адәмнәр дә ул кадәр гыйлемне ихата кыла [иңли] алмаслар. Чөнки һәмишә [һаман] җәгърәфия китапларына рожуг [кайту] вә мәмәрсә [күпер] белән йир йөзенең хисса [өлеш] вә кыйтгалары вә ул кыйтгаларның бер-беренә нисбәте вә мөнәсәбәте озаглары зиһен тактасына мәнкуш булып [бизәлеп], бер тарафны яки бер диярны [илне] белергә хаҗәт булганда, зиһен тактасына караса, дәрхаль [шундук], ул тарафның әхвале әҗмәлә мөшаһәдә [шаһит булып] вә махсус кебек гүяки ул йирләр күзнең алдында күренеп торган шикелле булыр... Бәс, бер адәм мәзкүр фәнне тәхсил итеп [казанып] әсраренә матләгъ булса [серләренә төшенсә], ул кемсәнәгә әхвале дөнья тәмаман заһир вә рәүшан булып [ачык һәм якты], вә сәфәр мәшәкатен чикмәенчә өендә ятып әтраф галәмнең хөдүд әрбәгасен [чикләрен] белеп, кулына аршин вә аркан тотмаенча ераклык вә якынлыкларын тәхминә [чама белән] белеп вә бәгъзе хосуста әсрар дәкыйкага вакыф вә ашна [аңлаучы һәм таныш] булыр».

Китапта әүвәл мондый география терминнары китерелә: җәгърәфия харитасы, әтрафы галәм (шималь, җәнүб, мәгъриб, мәшрикъ; алар арасында тагын шундый бүленеш китерелә: шималь гарби, шималь шәркый, җәнүб гарби, җәнүб шәркый). Су эчендә калкып торган җирләр: атау, ярты атау, бугаз, борын (Чукот борыны); коры җирдә: тау, ут тавы (вулкан), үтләвек (ике тау арасында үтә торган урын), яр яки яка (гарәпчә — сахил); сулар:



К.Насыйри. «Истыйлахәте җәгърәфия». Казан, 1890.

диңгез, елга, күл, ермак (җырмак), лиман (дулкын вакытында корабларны саклау өчен махсус казып эшләнгән сулык), гәрдаб (упкын, чоңгыл). География фәнендә киң кулланылышта булган глобус «йир керәсе» дигән термин белән бирелгән. Терминнарга иллюстрацияләр эшләнгән.

Аннары Азия (Госманлы мәмләкәте, Гарәбстан (географиясе, мәшһүр шәһәрләр, Кәгъба, Ямән өлкәсе), Иран, Әфганстан, Бәүҗистан, Төркестан,

Һиндстан, Чин (Кытай), Кашгар, Япония, Русия, Сибирия, Атаулар мәмләкәтләре), Австралия, Африка, Европа, Америка кыйтгаларына багышлана. Аларның чикләре күрсәтелә, андагы таулар, елгалар тасвирлана, дәүләтләрнең тарихы, географик үзенчәлекләре, шәһәрләре бәян ителә.

Китапның сүз башы хәзерге татар теленә күчерелеп, К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1953, 1956), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең икенче томына (1975) урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Истыйлахате җәгърәфия. Казан, 1890.

Әд.: Мөхәммәтов Х. Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеяләре. Казан, 1961.

Р.Ф.Исламов.

ИСХА́КОВ Вазыйх Мөхәммәтша улы (05.10.1927, Башкортстан АССРның Бәләбәй кантоны (хәзер Башкортстан Республикасы Чакмагыш районы) Туйнаш авылы) – 10.01.1985, Уфа), язучы, педагог, мөхәррир, Башкортстан АССР Язучылар берлеге әгъзасы (1966), Башкортстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1981), Башкортстан комсомолының Сәләм Галимов исемендәге бүләге лауреаты (1984).

Башкорт университетын тәмамлый (1964). 1958–1959 елларда — «Кызыл таң» газетасының әдәби хезмәткәре, 1962 елдан Башкортстан телевидениесе һәм радиотапшырулар комитетында мөхәррир булып эшли. 1964 елдан Башкорт университетында укыта. 1966–1968, 1973 елларда «Агыйдел» журналында мөхәррир урынбасары вазифасын башкара. 1968–1973 елларда Башкортстан АССР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркатибе.

В.Исхаков узган гасырның 60 еллар ахыры — 70 елларында Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары геройлары Хөсәен Мәүлетов, Шәһит Ходайбирдин, революционер Петр Зенцов, дипломат Кәрим Хәкимов, Муса Җәлил һәм шул вакыттагы тарихи вакыйгаларда катнашучылар турында мәкаләләр, очерклар, хикәяләр бастыра. Язучының «Мулланур Вахитов» исемле беренче китабы 1958 елда нәшер ителә. Башкорт телендә «Революционер тураһында хикәйә» (1960), «Ҡындан һурылды ҡылыстар» (1968), «Һаумы, генерал!» (1975), «Бәхтизин» (1974) романнары, «Тулҡындар ярға ҡаға» (1978), «Йылдар шаңдауы» (1986) повестьлары дөнья күрә.



В.М.Исхаков

Аның Каюм Насыйри турында «Ҙур ғалим, мәғрифәтсе» мәкаләсе игътибарга лаек. Автор биредә, мәгърифәтче К.Насыйриның олпат галим булуын, хезмәтләренең мөһимлеген ассызыклап, аның фәннең төрле тармагын колачлаган күпкырлы эшчәнлеген яктырта.

Хезм.: Ҙур ғалим, мәғрифәтсе // Башҡортстан пионере. 1965. 14 февраль.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ИСХА́КОВА Рима Мөхәррәм кызы (14.01.1964, Татарстанның Актаныш районы Колын авылы), педагог, методист. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2014).

Минзәлә педагогия училищесын (1983), Алабуга педагогия институтының физика-математика факультетын (1988), Казан педагогия университетын (татар теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча, 1998) тәмамлый. 1983 елдан — Мөслим районының Сикия сигезьеллык мәктәбендә укытучы, 1984

елдан — Башкортстанның Нефтекамск шәһәре 19 нчы балалар бакчасында тәрбияче, 1986 елдан — Чаллы шәһәренең 60 нчы, 19 нчы балалар бакчаларында тәрбияче, 1992 елдан — 3 нче, 9 нчы урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә укытучы, 2000 елдан — мәгариф идарәсенең методика үзәгендә методист, 2003 елдан дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениесе «Мирас» урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры, 33 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры урынбасары, 29 нчы гимназиядә укытучы булып эшли.



Р.М.Исхакова

Р.Исхакова күп еллар дәвамында «Татар милли педагогикасы» элективкурсын, «Татар теле һәм аның сөйләм культурасы» курсын, татар порталында «Яр Чаллы шәһәре татар теле һәм әдәбияты укытучылары ассоциациясе» һәм «Әдәбият укыту серләре» бергәлекләре җитәкчесе. Екатеринбург, Уфа шәһәрләре татар теле һәм әдәбияты укытучыларына дәрес эшкәртмәләре, методик ярдәмлекләр белән булыша, яңа технологияләргә корылган мастер-класслар үткәрә. Әхлак тәрбиясенә зур әһәмият бирә, әлеге юнәлештә Каюм Насыйриның «Китап әт-тәрбия» хезмәте таяныч була. Укучылары «Каюм Насыйриның этнография өлкәсендәге хезмәтләре» темасы буенча федераль фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгышлар ясыйлар.

Хезмәтләре рус телле укучыларны татар әдәбияты белән таныштыру һәм кызыксындыруга, татар теле һәм әдәбияты укыту процессындагы яңа технологияләр куллану тәжрибәсенә карый.

Хезм.: Балачак дөньясында: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен хрестоматия (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан, 2013 (автордаш); Дуслар белән бергәләп: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен хрестоматия (рус телендә сөйләшүче балалар өчен. Казан, 2013 (автордаш); Кояшлы ил: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 4 нче сыйныфы өчен хрестоматия (рус телендә сөйләшүче балалар өчен. Казан, 2013 (автордаш).

Ф.Г.Камальтдинова.

ИСХАКЫЙ (Исхаков) Гаяз (Мөхәммәтгаяз) Гыйлаҗетдин улы (мөһаҗирлектәге тәхәллүсе — Иделле) (22.02.1878, Казан губернасының Чистай өязе Яуширмә авылы – 22.07.1954, Төркиянең Әнкара шәһәре; Истанбулда җирләнә), язучы, публицист, журналист, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе; XX йөз башы татар яңарыш әдәбиятына нигез салучыларның берсе.

Чистайдагы Закир Камали (1890–1893), Казандагы «Касыймия» (1893–1897) мәдрәсәләрендә, Казан татар укытучылар мәктәбендә (1898–1902) белем ала. 1902 елның көзеннән Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. 1903 елның җәендә университетка керү нияте белән Казанга килә, ләкин ата-анасының ихтыяры белән туган авылына кайтырга һәм мулла вазифаларын башкарырга мәҗбүр була. 1904 елда кабат Казанга килә, шул чордан башлап үзен тулысынча иҗтимагый-сәяси һәм әдәби эшчәнлеккә багышлый. 1905–1907 елларда милли хәрәкәттә актив катнаша: шәкертләрнең яшерен «Берек» оешмасын төзи, Казанда татар яшьләренең яшерен «Хөррият» сәяси җәмгыятен җитәкли, татар эсерларының «Таңчылар» төркеме башлыгы була. Россия мөселманнарының «Иттифакъ әл-мөсли-

мин» фиркасе съездларында радикал татар яшьләре вәкиле буларак катнаша. Гамәлдә «Таң йолдызы», «Тавыш», «Таң мәҗмугасы» газеталарында мөхәррир вазифасын башкара. Революцион эшчәнлеге, хакимияткә каршы ясаган чыгышлары өчен күп тапкыр кулга алына; Чистай, Казан, Мәскәү, С.-Петербург төрмәләрендә утыра, Архангельск губернасына сөргенгә озатыла. 1909–1911 елларда сөргеннән качып, ике тапкыр Төркиягә барып чыга, анда әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнә: «Сират әл-мөстәкыйм» («Туры юл»), «Төрк дәрнәге дәргиси» («Төрек җәмгыяте мәҗмугасы») исемле төрек басмаларында языша.

1913 елның язында төрмәдән азат ителгәннән соң, Мәскәүдә, Петроградта яши: «Ил» газетасын нәшер итә. 1917 елгы Февраль революциясен хуплап каршылый, Вакытлы хөкүмәтнең милли сәясәтен яклап чыга. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче съездында Идел буе һәм Урал төрки-татарлары өчен милли-мәдәни автономия — Идел-Урал Штаты төзү фикерен алга сөрә. Аның бу идеясе Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче съездында да (Казан, 1917), Милләт Мәҗлесендә дә (Уфа, 1917–1918) хуплау таба. Г.Исхакый Бөтенроссия мөселманнары Милли Шурасы әгъзасы итеп сайлана. Совет хакимиятен кабул итми. Большевиклар эзәрлекләвеннән качып, Себер якларына (Казакъстанның Петропавловск шәһәренә) китә. Анда «Маяк» исемле татар газетасы чыгаруда катнаша (1918–1919).


1919 елда, Версаль тынычлык конференциясендә катнашу өчен, Ерак Көнчыгыш аша Европага юнәлә. 1920 елның мартыннан 1922 елның җәенә кадәр — Парижда, аннары Берлинда яши. 1925 елдан — Төркиядә; Истанбулда «Түрк юрду» журналында, «Җөмһүрият» газетасында актив хезмәттәшлек итә. 1927 елда Польшага күчеп килә, анда «Идел-Урал комитеты»н оештыра, Варшава университетының Шәрекъ факультетында төрек теле укыта. 1931 елның декабреннән 1932 ел башына кадәр Иерусалимда үткән Бөтендөнья мөселманнар конгрессында катнаша, докладында Совет Россиясендә ислам динен кысу, мәчетләрны ябу, дин әһелләрен эзәрлекләү турында сөйли. Бу мәсьәлә белән ул Мисыр, Иран, Гыйрак, Әфганстан, Йәмән дәүләтләре башлыкларына, шулай ук Марокко солтанына һәм Рим папасына мөрәҗәгать итә.

1933–1936 елларда Ерак Көнчыгыш илләре буйлап сәяхәт кыла, Кытай, Маньчжурия, Япония, Кореяда яшәгән төрки-татарларны берләштерү, Мукден конгрессын оештыру һәм үткәрү, «Ерак Көнчыгыш төрки-татар мөселманнарының дини-милли Идел-Урал мәркәзе»н төзү буенча зур эш алып бара. 1936 елда Варшавага әйләнеп кайта, 1939 елда Польшага фашистлар Германиясе басып кергәч, Төркиягә китә һәм соңгы көннәренә кадәр шунда яши. Мөһаҗирлек елларында «Милли юл» (1928–1930), «*Яңа милли юл*» (Берлин, Варшава, 1930–1939) журналлары, «Милли байрак» (Кытай, Мукден шәһәре, 1935–1945) газетасы нашире һәм мөхәррире була. Бу басмаларда ул татарларны югалган дәүләтчелекләрен кайтару, милли азатлыкка ирешү өчен берләшергә чакыра.

Иҗат юлының башлангычы 19 йөз ахыры – 20 йөз башына — татар әдәбияты үзенең Яңарыш чорына аяк баскан дәвергә туры килә. Г.Исхакыйның беренче басылган әсәре — «Тәгаллемдә — сәгадәт» хикәясе (1897). Анда автор җәдит мәдрәсәсе шәкерте Хәлимнең милләт хадиме булып җитешүен һәм шәхси тормышында да бәхеткә ирешүен тасвирлый. Әлеге хикәядә күтәрелгән мәсьәләләр «Бай угылы» по-

вестенда (1897) да чагылыш таба. «Кәләпүшче кыз» повесте (1900) язучы буларак зур танылу китерә. «Өч хатын белән тормыш» (1900), «Ике гашыйк» (1902) пьесаларында, «Очрашу, яки Гөлгыйзар» повестенда (1903) татарлар арасында киң таралган иске феодаль-патриархаль гореф-гадәтләр һ.б. тәнкыйтьләнә. Язучының үз иҗатында гына түгел, бәлки 20 йөз башы татар иҗтимагый һәм әдәби тормышында зур вакыйга булган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» мәгърифәтчелек антиутопиясендә (1902–1904) татарларның ерак бабалары — болгарлар югары цивилизациянең 10–13 йөзләрдә чәчәк ату чорын кичерүләре, 19–20 йөзләргә җиткәндә, икътисади һәм рухи төшенкелек кичереп, әхлакый бозыклыктан, йогышлы яман чирләрдән кырылып, 20 йөз ахырында милләт буларак тарих мәйданыннан юкка чыгулары турында тасвирлана. Думага сайлаулар һәм революцион хәрәкәткә бәйле чынбарлыкта булган вакыйгалар Чистай төрмәсендәге хәлләрне сурәтләгән автобиографик һәм публицистик язмалар рәвешендә «Зиндан» повестенда (1907) чагылыш таба. Татар пролетар әдәбиятының үрнәге булган «Тартышу» (1908) драмасында социал-демократларның, «таңчы»-эсерларның, народник яшьләрнең самодержавиегә каршы чыгышлары сурәтләнә. Народниклык идеяләренең көчле тәэсире «Мөгаллим» (1908) һәм «Мөгаллимә» (1913) драмаларында аеруча ачык күзәтелә. Язучы иске карашлы муллаларның схоластик фикерләүләреннән, җаһиллекләреннән «Җәмгыять» (1909) һәм «Кыямәт» (1909) комедияләрендә ачы көлә.

1910 елларда Исхакыйның иҗтимагый-сәяси карашлары һәм сәнгатьчә фикерләве җитди үзгәрешләр кичерә. Ул, инкыйлаби-сыйнфый көрәш идеяләреннән баш тартып, гомуммилли мәнфәгатьләрне яклау юлына баса, бөтен көчен татар җәмгыятенең төрле катлауларын берләштерүгә һәм милли үзаңны үстерүгә юнәлтә. Милли кыйммәтләрне чагылдыру ягыннан «Сөннәтче бабай» (1911) повесте аерылып тора. «Зөләйха» (1912) романтик трагедиясендә мөселман татарларны көчләп чукындыру һәм урыслаштыру сәясәте күрсәтелә. «Остазбикә» (1915) повестенда мөселман мәдәниятенә хас кыйммәтләр — гаилә, балаларга карата мәхәббәт, ананы хөрмәтләү, милләткә тугрылык алга чыгарыла. «Ул әле икеләнә иде» (1914) һәм «Ул әле өйләнмәгән иде» (1916) повестьларында милләтара никахлар мәсьәләсе күтәрелә.



Г.Г.Исхакый

Г.Исхакый — төрки халыкларның азатлык хәрәкәте тарихына, шулай ук журналистика, әдәбият тарихына һәм әдәби тәнкыйтькә багышланган күп кенә әсәрләр авторы. Мәкаләләрендә Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы, Ризаэтдин Фәхретдин кебек татар мәгърифәтчеләренең фидакарь эшчәнлекләре яктыртыла. Мәсәлән, «Тәрҗеман» газетасының (1902) К.Насыйри вафаты мөнәсәбәте белән аңа багышланган санында — «Габделкаюм әфәнденең вафаты», «Яңа милли юл» һәм «Түрк юрду» журналларында «Габделкаюм ән-Насыйри» (1937) һәм «Абдулкаюм әл Насыйри» (1942) мәкаләләре дөнья күрә. Аларда автор галимнең тормыш юлын күздән кичереп, аның мәгърифәтчелек өлкәсендәге казанышларын, фәннең төрле тармакларындагы фәнни эшчәнлеген, татар тел белеме һәм

әдәбияты үсешенә керткән өлешен югары бәяли.

Совет хакимияте елларында эмигрант язучы һәм «халык дошманы» дип тамгаланган Г.Исхакыйның әсәрләре онытылуга дучар ителә. 1980 еллар ахырында гына аның мирасы халыкка кире кайтарыла. 1991 елда ТР Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләге булдырыла, соңрак Яушырмә авылында язучының музее ачыла.

Әсәр.: Габделкаюм әфәнденең вафаты // Тәрҗеман. 1902. 15 сентябрь; Габделкаюм ән-Насыйри // Яңа милли юл. 1937. №10; Әсәрләр. Казан, 1998–2005. Т. 1–4, 6, 8; Abdulkayyum el Nasiri // Türk Yurdu. 1942. №7.

Әд.: Миңнегулов Х. Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан, 2004; Мусин Ф. Гаяз Исхакый. Казан, 1998; Харрасова Р. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. Казан, 2002; Шәмсутова А. Гаяз Исхакый иҗатында феминистик проблемаларның идеал-эстетик эволюциясе. Казан, 2003; Сахапов М. Исхаки и татарская литература XX века. Казань, 2003.

И.Х.Хәлиуллин.

ИША́ЕВ Нуретдин (?–?), Каюм Насыйри турында хатирәләр авторы. Аның истәлеге беренче мәртәбә «Шура» журналында 1912 елда дөнья күрә. Аннан соң әдәбиятчы Фатыйма *Ибраһимова* тарафыннан күпмедер кыскартулар белән 1996 елда Казанда «Әдәби мирас»ның 3 нче китабында бастырыла.

Н.Ишаев үзенең истәлегендә Каюм Насыйри белән 1898 елның май урталарында күрешүләре турында яза. Ул Фәйзерахман хәзрәт белән Уфа, Оренбург, Самара һәм Казан шәһәрләре буйлап сәяхәткә чыга һәм, Казанга килгәч, К.Насыйри белән очраша. Шул күрешүне түбәндәгечә тасвирлый: «...Екатерининский урамда, сул якта, Аитов йортында, сул тарафта кечерәк бер агач йортка кердек. Бер бүлмәне үтеп икенче бүлмәгә кергәч, ике тарафта туп-тулы яңа басмадан чыгып өлгергән китап уртасыннан тар гына юл киткән. Аяк астына яшел үлән җәйгән, төрле чәчәкләр тутырган дивар тузанлы — чиста түгел. Түрдәрәк, урталыкта, борынгы мәдрәсәләрдә тотыла торган тәбәнәк өстәл, өстенә бернәрсә дә җәймәгән. Өстәлдә ике касә вә бер шакмак шикәр, бер телем арыш икмәге, самавар бар. Ләкин самавар җизме, бакырмы — беленерлек түгел, кап-кара керләнгән. Шул өстәл янында Бәләбәй өязе Бурангол башкорты рәвешендә киң якалы күк киндер күлмәк кигән, якасында изү бау (ялау), башында балан кагы кеби түбәтәй, аягын бөкләп утырган Габделкаюм абзый чәй эчәдер. Бер ягында ачылып куелган китап бар. Сәлам бирдек һәм барып күрештек. Әсәрләре турында сүз кузгатып, бераз алырга ниятебез барлыкны белдердек. Шуннан соң бераз кәефе килеп, китапларны үзе бастырырга көче җитмәгәнен, наширләр илтифат кылмаганлыкны, безнең милләт уку эшене алга алмаганлыкны, Казан халкында хатын-кыз бозыклыгыны, кием-салымда кыяфәт алмаштыруларыны сөйләп зарланды. Башкача бик хәтердә калырлык сүз чыкмады. Бераз рисаләләрен алып, исәнләшеп чыгып киттек». Аннан соң Н.Ишаев 1901 елда Истанбулда Садри Максуди белән очрашуын өскә төшереп: «Габделкаюм әфәнде янында булган вакытымда Садри әфәнде кебек кисәтү кылучы булган булса иде, бераз мәгълүмат алган булыр идем», — дип, К.Насыйриның игътибарлы, гыйлемле кеше булуына сокланuын белдерә. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. №22; Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләр. Әдәби мирас. 3 нче китап. Казан, 1996.

Ф.С.Гыйниятуллина.

Й

ЙӨЗ ИЛЛЕ́ БИШЕНЧЕ́ ГИМНА́ЗИЯ, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының башлыча татар телендә гомуми белем бирү муниципаль бюджет уку йорты. 1995 елда ачыла, Казан шәһәренең Яңа Савин районында урнашкан. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2021).

Эшчәнлегендә татар халкы тарихына һәм мәдәниятенә карата мәхәббәт, милли үзаң, башка халыкларның гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә, гуманитар асылда белем бирүгә (полилингваль — татар, рус, инглиз телләрендә укыту) юнәлеш тота. Туган тел (татар теле), әдәбият укыту буенча республикакүләм тәжрибә туплау мәйданчыгы. Гимназия укучылары халыкара, бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында призлы урыннар, төрле иҗади бәйгеләрдә («Татар егете», «Татар кызы», Г.Тукай исемендәге халыкара шигырь сөйләүчеләр, бөтенроссия «Илһам» яшь язучылар конкурслары, «Сәйяр» мәктәп театр коллективлары фестивале) җиңүләр яулыйлар; укытучылар җитәкчелегендә күренекле татар мәгърифәтчеләре, педагоглары һәм җәмәгать эшлеклеләренә багышланган республика педагогик укуларында (Казан шәһәренең 71 нче мәктәбендә), К.Насыйри исемендәге халыкара фәнни-гамәли конференциядә (Яшел Үзән шәһәренең 10 нчы гимназиясендә), яшүсмерләрнең төбәкара фәнни-гамәли конференциясендә (Казан шәһәренең 81 нче мәктәбендә) катнашалар.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк милли мәгарифне үстерүдәге казанышлары өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

К


«КАБУСНАМӘ ТӘРҖЕМӘСЕ́», яңа фарсы телендә язылган урта гасырлар проза әсәре. 1082–1083 елларда Табаристанның Каспий провинцияләрендә идарә иткән Зийаридлар династиясе әмирләренә караган Кәйкавус бине Искәндәр падишаһ (1021–1098) тарафыннан төзелә. «Кабуснамә» шаһзадәләр көзгеләре жанрында Кейкавусның яраткан улы һәм варисы Гыйланшаһка үгет итеп язылган һәм авторның бабасы, Гурган хакиме Зийарид Кабус ибне Вушмгир хөрмәтенә «Кабуснамә» дип аталган. Әлеге әсәрнең басмалары һәм кулъязмалары мөселман халыклары арасында киң таралыш ала. Ул шулай ук иске төрек (госманлы) теленә күчереп языла.

Каюм Насыйри татар теленә тәрҗемә итү өчен «Кабуснамә»нең госманлы язучысы Әхмәд бине Ильяс тарафыннан башкарылган вариантын файдалана, китапны 1882 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер итә. Бу хакта Кереш сүзендә ул: «Ошбу «Кабуснамә» китабы әүвәл башта фарсы теле үзеренә тасниф кылынып, госманлы халкыннан Назмизадә әфәнде вә гайреләре госманлы теле үзрә тәрҗемә кылган булсалар да, Рус мәмләкәтенең мөселманнары өчен госманлы теле авыр вә мәгънәсен фәһемләү авыр булганлык җәһәтеннән гыйлемем ихата кылган кадәр сәхи вә иҗтиһад [гыйлемем җиткән кадәр юмартлык һәм тырышлык] сарыф кылып госманлы теленнән үз телемезгә тәрҗемәсенә шөругъ кылдым [башладым]...», — дип белдерә.

Әдәби әсәрнең эчтәлеге үгет-нәсыйхәт бирүдән гыйбарәт, ул дидактик жанрда чәчмә ысул белән язылган. Әхмәд бине Ильяс нөсхәсеннән тәрҗемә ителгән әсәрнең композицион төзелеше 44 бүлектән гыйбарәт булып, Аллаһы Тәгаләне тану, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сыйфатларын тасвирлаудан башлап, тормыш-көнкүрешнең бик күп өлкәләрен үз эченә ала: ата-ана хакын хаклау, һөнәр үзләштерү, яшьлек һәм картлык, ашау-эчү әдәбе, мосафирларга һәм кунакларга хөрмәт күрсәтү, кеше белән дуслык мөнәсәбәтләре, сату-алу әдәбе, бала тәрбияләү һ.б. Әсәрдә, ата-ана хакын хаклау турында: «И угыл, вәҗебдер ки, ата-ана хакларын вә хөрмәтләрен саклагайсың вә асылыңны олуглайсың. Үз нәфесеңне олугламыш вә олугзадә булырсың, үз асылыңның хөрмәтен яхшы саклагайсың вә дәхи саклан. И угыл, әйтмә ки: «Атам-анамның гарызлары мине вөҗүдкә китермәк түгел иде, бәлки үз арзулары үзренә килмәк иде», димә. Чөнки фил-хакыйка синең вөҗүдкә киләсең сәбәпле алар кавыштылар вә дәхи зинһар әйтмә: «Ата-анам минем үзремдә ни хаклары бар», димә. Чөнки атаң-анаң синең үзеңдәге хаклары әүвәл сине алар дөньяга китерделәр. Атаң-анаң булмаса, син дөньяга

килмәс идең. Аллаһы Тәгалә шөйлә сәбәп кылмыштыр...» дигән нәсыйхәтләр бирелә.

Әсәр *Гөлнар ханым* (шәркыятьче О.С.Лебедева) тарафыннан К.Насыйри ярдәмендә 1886 елда рус теленә тәрҗемә итеп бастырыла. Бу турыда ул китапның беренче битендә: «Әлеге әсәр фарсы телендә язылган һәм төрек теленә, ә төрек теленнән татар теленә Каюм Насыйров тарафыннан Русия мөселманнарына ачык булсын өчен тәрҗемә ителгән. Ә татар теленнән О. С. Л.», — дип искәртелә.



К.Насыйри. «Кабуснамә тәрҗемәсе». Казан, 1882.

«Кабуснамә тәрҗемәсе» 1898 елда Казан университеты басмаханәсендә кабат басылып чыга. Әсәрнең утыз бишенче «Шигырь вә шагыйрьләр әхвале бәянында» бүлеге оригиналда һәм хәзерге татар теленә күчермәсендә Каюм Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1953; 1956; 1974, 2 т.), «Әсәрләр»енә (хәзерге татар теленә күчермәсе, 1971), тулы тексты — 4 томлык «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томына (2006), унике бүлеге шәркыятьче, тел галиме Г.Г.Зәйнуллинның «Әдәп-әхлак дәресләре» (2014) уку ярдәмлегенә урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Кабуснамә тәрҗемәсе. Казан, 1882; шул ук. Кабуснамә тәрҗемәсе. Казан, 1898.

Әд.: Зәйнуллин Г.Г. Әдәп-әхлак дәресләре: уку ярдәмлеге. Казан, 2014; Катанов Н. «Кабус-намэ тэрджемесы» (перевод книги Кабус-намэ). Казань, 1898. Типогр. ун-та. 140 стр. // Деятель. 1898. №5.

Р.Ф.Исламов.

«КАВАГЫЙДӘ КИТАБӘТ» («Кагыйдәләр китабы»), татар теле буенча уку-укыту әсбабы. Каюм Насыйри тарафыннан төзелә һәм 1892 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә. Язмада һәм сөйләмдә хаталар булдырмау максатыннан сүзне дөрес язу һәм стилистик алымнар турында кагыйдәләрдән гыйбарәт.

Кереш өлештә автор хезмәтнең максатын: «Мәгълүм ула ки, һәрбер телдә китабәт вә язу дигән нәрсә хәрефләрнең бер-бере белән кушылуыннан хасил булган кәлимәләр вә гыйбрәтләрдер. Вә гәр масдарит (фигыль) мәгънәсен игътибар кылынса, хәрефләрне бер-беренә кушып каләм васитасы (арадашлыгы) белән ул кәлимәләрне кәгазь өстенә китермәктән гыйбарәттер. Мәдәниятле һәрбер адәмнең ике теле булып, берсе анасыннан сөт имгән мөддәттә [вакытта] үгрәнгән теледер. Икенчесе дәхи бер остазга тәгълимгә бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган теледер. Әмма сөт телендә безнең эшемез юк, чөнки бу кадәресе анасының шәһнедер [үзенчәлегедер] вә атасы тарафыннан бер гафләттер...», — дип аңлата.

Һәр аңлатма иллюстратив материаллар белән ныгытып барыла. Аңлатмалар тәфсилләп бирелә, аерым алганда, «баш» һәм «данә» сүзләренең дөрес кулланылышы түбәндәгечә

аңлатыла: «Баш» яки гарәпчә «рәис» дип сөйләшүләр хайванат әһлия хакында күбрәк мөстәгъмәлдер [кулланыладыр]. Мәсәлән, бер баш ат, ике баш сыгыр, биш баш сарык. Вә бал корты хакында йортларын зикер кылып [искә алып], алты баш умарта, диләр. Әмма кошлар җөмләсеннән: бер данә тавык, биш данә үрдәк, диләр. Вә кәзалик [тагын] макулаттан ике данә алма, вә «гадәд» лафзының истигъмалы кәзалик «данә» лафзы кебектер («сан» сүзенең кулланылышы тагын «данә» сүзе кебектер). Әмма телемездә «данә» лафзы газиз әл-вөҗүд булганы нәрсә хакында мөстәгъмәл күренәдер. Ике данә алмас, биш данә моржа вә кәзалик ун данә китап вә дәхи әйтерләр: аның бары бер данә угылы бар».

Чыг.: Насыйри К. Кавагыйде китабәт. Казан, 1892.

Р.Ф.Исламов.

«КАВАГЫЙДӘ КЫЙРАӘТӘ РУСИ́Я» («Русская азбука для первоначального чтения на русском языке» — «Рус телендә беренчел уку өчен рус әлифбасы»), башлап рус телен өйрәнү өчен уку әсбабы. Каюм Насыйри тарафыннан тәрҗемә ителә һәм 1890 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә.

Уку әсбабының структур төзелеше 50 сабакка (дәрескә) бүленә. Башта рус алфавитындагы хәрефләр исемнәре белән китерелә, аннары зур һәм юл хәрефләренең кулдан язылыш, укылыш үрнәкләре гарәп хәрефләре белән бергә бирелә. Телне күнектерү өчен төрле сүзләрнең язылышлары шулай ук гарәп графикасы белән бергә тәкъдим ителә. Аннан соң сүзләр фәкать рус хәрефләрендә генә язылган. Алга таба бер иҗекле сүздән башлап күп иҗекле сүзләргә күчелгән. Ахырда уку материалы буларак төрле эчтәлектәге мәкаләләр урнаштырылган.

Китап ахырында К.Насыйри: «Әмма нәсыйхәт шулдыр ки, русча укытучы мөгаллимнәр һәр сүзнең мәгънәсен әйтеп вә һәр җөмләнең мәхсулын (барлыкка килүен) бәян кыйлып укытсыннар. Дәхи укучының үзенә дә моннан ни аңладың дип, бәян кыйлдырсыннар. Һәрбер телне укытканда калә



К.Насыйри. «Кавагыйде кыйраәте русия». Казан, 1889.

әйтте, бекавел әйтер (әйтте, сөйләр) дип кенә файда хасыйл булмыйдыр», — дип киңәш бирә.

Чыг.: Насыйри К. Кавагыйде кыйраәте русия. Казан, 1890.

Р.Ф.Исламов.

«КАВАГЫЙДӘ ЛИСАНӘ ГАРӘ́Б» («Кавагыйде лисане гарәб, ягъни гыйльме сарыфта вә гыйльме нәхүдән» — «Гарәп теле кагыйдәләре, ягъни грамматика һәм синтаксис гыйлеменнән»), уку һәм ятлау өчен билгеләнгән китап. Каюм Насыйри тарафыннан язылып, 1896 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә.

Төрле гарәп грамматикаларыннан сайлап алынган өземтәләр гарәп һәм фарсы телләрендә язылган. Әүвәл гарәп сүзләрендәге хәрефләр, аннары исем категориясе һәм аның төрләнеше, фигыльләр һәм аларның формалары китерелә. Һәр кагыйдә гарәп телендәге мисаллар белән ныгытыла. Ләкин шунысы, сүзләрдәге сузык аваз-лар хәрәкәләр белән бирелми. Тышлыгында әйтелгәнчә, китап бер ел эчендә үзләштерүгә исәпләнә. Төрки телләр галиме, филология докторы, чагыштырма тел белеме докторы Н.Ф.*Катанов*, әлеге хезмәтне анализлаганнан соң, аның уңай якларын һәм кимчелекләрен күрсәтеп, аңа бу вакыт эчендә төшенеп бетү мөмкин түгеллеге, дәреслек авторының аңарчы ук гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән балаларны һәм аларга белем бирергә сәләтле мөгаллимнәрне күздә тотуы турында нәтиҗә ясый. Шул рәвешле «гарәп грамматикасын татарча өйрәтмәүне татар галимнәренең «затлы» гарәп телен «тупас мужик теле» белән бозарга теләмәүләрендә күрә.

Чыг.: Насыйри К. Кавагыйде лисане гарәб. Казан, 1896.

Әд.: Катанов Н. Книга «Кава иди-лисани- араб» (правила арабского языка), составлена Абду'ль-Каюмом Насыровым. Казань, 1896. Типография университета. 74 стр. // Деятель. 1897. № 2.

Р.Ф.Исламов.

КАВИ́ЕВ Хәмит Сәлим улы (1906, Казан губернасының Чабаксар өязе (хәзер Чуаш Республикасының Козловка районы) Әлмән авылы – 15.07.1944, Украина ССРның Волынск өлкәсендәге Друженополь авылы), педагог, язучы, публицист; Бөек Ватан сугышында катнаша, өлкән лейтенант, танк командиры. Бабасы Габделнасыйров (Нигъмәтуллин) Габделкави Насыйри улы ягыннан нәселләре шушы авылга нигез салучыларга барып тоташа). 1882 елда Әлмән авылына мулла итеп билгеләнә, кырык ел дәвамында шушы вазифаны башкара. Аның хатыны, ягъни Хәмитнең әбисе Нәфисә – мәгърифәтче К.Насыйриның туганнан туганы. Әлмән авылының иң матур урыны якташлары тарафыннан хәзер дә «Кави мулла нигезе» дип йөртелә.



Х.С.Кавиев

Казан педагогия техникумын (1926), Көнчыгыш педагогия институтының биология факультетын (1931) тәмамлый. 1926 елдан Казанда урта мәктәпләрдә, техникумнарда биология һәм география фәннәрен укыта. Техникумда укыган елларында татар язучылары белән аралаша башлый, әдәби түгәрәкләргә йөри. Илебезнең төрле почмакларына сәяхәт кыла һәм шул сәфәрләрдә күргәннәрен язып бара. Соңыннан әлеге материаллар нигезендә фәнни-популяр жанрдагы хикәя-повестьлар иҗат итә. Аның «Кавказ таулары аркылы җәяү» (1930), «Безнең яз» (1931), «Идел буенда йөрү юллары» (1931) «Боз диңгезенә таба» (1932), «Балалар күмер өчен көрәшәләр» (1932), «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) китаплары яшүсмерләр һәм мәктәп укучылары тарафыннан яратып укыла. Язучы илебезнең географик үзенчәлекләрен, казылма байлыкларын, җирле халыкларның көнкүреше, мәдәнияте хакында көндәлек матбугат битләрендә дистәләрчә мәкаләләр бастыра. Мехчылар техникумы укучыларының Казан–Мәскәү маршруты буйлап чаңгы походын оештыра. Яшь буынны тәрбияләүгә зур өлеш керткәне өчен 1936 ел-

да аңа Мәскәүдә Тышкы сәүдә халык комиссары имзасы белән сәгать тапшырыла. 1937 елда ерак Арктикага оештырылган сәяхәттә махсус хәбәрче буларак катнаша.

Х.Кавиев үзен скульптура өлкәсендә дә сынап карый. Туганнарының истәлекләрендә аның К.Насыйри бюстын ясавы телгә алына. Галимнең 1930 елларда иҗат ителгән әлеге бюсты, бер



Х.С.Кавиев. «Каюм Насыйри». Гипс. 1930 еллар.

күзенең кысыграк, күлмәк баулары-ның да шундый ук рәвештә сурәтләнүеннән чыгып, чордашлары тарафыннан Каюм Насыйриның беренче портретын ясаган Госман *Арсланов* картинасына нигезләнеп эшләнгән дип фаразлана. Урнаштырылган ташына «Каюм Насыйри» дип язылган була. Бюст сакланмаган, безнең көннәргә бары фоторәсеме генә килеп җиткән. Кавиев үз чорының күп кенә татар зыялылары Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Гомәр Гали, Гази Кашшаф, Абдулла Әхмәт һ.б. белән якыннан аралаша. Мехчылар техникумында эшләгәндә театр труппасы оештыра.

1941 елның сентябрендә Х.Кавиев фронтка китә. Кызыл Армия өлкән лейтенанты дәрәҗәсендә, танк командиры вазифасында Идел буеннан көнбатыш чикләргә кадәр сугышчан юл уза. 1944 елның 15 июлендә Украина ССРның Волынь өлкәсендәге Дружеполь авылы тирәсендәге сугышларның берсендә батырларча һәлак була. Маршал Г.Жуковның мемуарларында Х.Кавиевның әлеге батырлыгы турында телгә алына.

Медальләр белән бүләкләнә.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. Казан, 1986; Самат Шакир. Мәрмәргә уелган исем // Казан утлары. 1980. № 5.

Ф.Г.Камальтдинова.

КАЗА́Н, борынгы шәһәр; Казан ханлыгының (1438–1552), Казан губернасының административ үзәге (1708–1920), хәзер ТРның башкаласы. Иделнең сул ярында, Казансу елгасының Иделгә койган урынында урнашкан. Мәйданы — 1434 дисәтинә (1904). 1897 елда анда 130 мең кеше яши, шул исәптән руслар — 81,7 %, татарлар — 15,8 % тәшкил итә.

Идел — Чулман төбәгендә сәүдә-һөнәрчелек белән шөгыльләнүче болгар сәүдә үзәкләренең берсе буларак 10–11 йөзләр арасында Казансу елгасының түбәнге өлешендә нигезләнә. 10 йөз башында Идел буе Болгар дәүләте төзелү һәм Балтыйк илләреннән Көнчыгышка таба сузылган Евразия сәү-



Казан Кремле күренеше. 1870 еллар.

дә юлларының (Бөек Идел юлы) барлыкка килүе һәм үсүе моңа этәргеч бирә. Соңрак анда сәүдә-һөнәрчелек бистәләре формалаша. 1236–1240 елларда монгол яулары алдыннан һәм аннан соң Чулман аръягыннан күченеп килүчеләр исәбенә шәһәр халкы күпкә арта, һәм Алтын Урда чорында ул Урта Идел буендагы эре шәһәрләрнең берсенә әверелә. Рус елъязмаларында Казан 1399 елга карата әмирлек үзәкләренең берсе буларак искә алына. 14 йөз ахыры 5 йөз башында төбәктәге башка шәһәрләр арасында Казанның абруе зур була. 1420 елларда Казан һәм аның биләмәләре белән Жүчиләр нәселе вәкиле Гыясетдин идарә итә. 1430 елларда шәһәр Идел буендагы сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәккә әверелә.

Казан 1438 елдан мөстәкыйль дәүләт — Казан ханлыгы башкаласы. 15–16 йөз Европа карталарында Казан зур сәяси һәм икътисади мәркәз буларак күрсәтелә. Аның уңайлы җирдә урнашуы төрле илләрнең сәүдәгәрләрен үзенә җәлеп итә, Идел һәм Чулман буенда, Урал алдында яшәгән халыклар аның белән икътисади-сәүдә элемтәләре урнаштыралар. Казаннан ерак түгел Сәүдәгәрләр утравында халыкара ярминкә эшли. Ярминкәләр шәһәрнең үзендә дә (Ташаяк базары), бистәләрдә дә (Арча кыры) үткәрелә.



Казан университеты. 1879 ел.

Төрки-мөселман мәдәнияте үзәкләренең берсе буларак, Казан зур әһәмияткә ия була. Аның эчке һәм Мәскәүгә карата тышкы сәясәте күбесенчә хәрби һәм икътисади (нигездә, Идел буендагы сәүдә юлларында хакимлек итү өчен) көндәшлек мөнәсәбәтләреннән чыгып билгеләнә. Рус хөкүмәте 15 йөзнең 2 нче һәм 16 йөзнең 1 нче яртысында Казанга каршы дистәдән артык тапкыр хәрби яу оештыра. 1552 елның 2 октябрендә, җиде атналык камалыштан соң, шәһәрне Явыз Иван гаскәрләре яулап ала. Ул тулысынча диярлек җимертелә, халыкның күпчелеге һәлак була, бер өлешен әсирлеккә алып китәләр. Казан тарихында яңа чор башлану белән, милли гореф-гадәтләр һәм традицион яшәү рәвеше гаять зур үзгәрешләр кичерә. Татар мөселман шәһәре рус хәрби, идарә һәм дини үзәккә, көнчыгыштагы җирләрне колонияләштерүнең терәк пунктына әверелә. Казан белән башта — рус патшасы наместниклары, 1550 еллар ахырыннан Мәскәү билгеләгән воеводалар идарә итә. 1565–1568 елларга караган теркәү кенәгәсе күрсәткәнчә, Рус дәүләтенең 40 тан артык төбәгеннән күчерелгән руслар (һөнәрчеләр, осталар, сатучылар, ямчылар һ.б.) Казан бистәләренә килеп төпләнәләр. Татарларга яшәү урыны шәһәрнең читендә, Кабан күле һәм Болак тирәсендә билгеләнә, монда Татар бистәсе барлыкка килә. 1560 елларда шәһәрнең мәйданы 110 гектар чамасы тәшкил итә, анда 7 урам, 130 дан артык тыкрык була. 17 йөздә Казанда 1652 хуҗалык, 5432 ир-ат исәпләнә; шулай ук күп кенә хәрбиләр һәм башка социаль катлау вәкилләре яши. 1661–1663 елларда, мәсәлән, шәһәр гарнизонында 287 дворян, 2389 укчы, 43 тупчы, 799 йомышлы татар һәм морза, 337 яңа чукындырылганнар һәм 168 әҗнәби булуы мәгълүм.

1708 елдан Казан — губерна үзәге. 1722 елда Иранга каршы яу белән барганда шәһәрдә Россия императоры Пётр I була. Ул идарә иткән чорда Казан Россия империясенең мөһим административ һәм сәнәгый үзәгенә әверелә. 18 йөздә шәһәр Казансу елгасыннан көнбатыш һәм төньяк тарафларына киңәя башлый. Аның чикләренә көнбатышта — Мокрый һәм Ямчылар бистәләре, көнчыгышта Фёдор һәм Подлужный бистәләре керә. 18 йөзнең 1 нче яртысында Казанда шәһәр җәмәгатьчелек үзидарәсенә нигез салына, магистрат (1718), ратуша (1728) барлыкка килә.

1740–1750 елларда Казан архиепископы Лука (Конашевич) җитәкчелегендә Казан һәм Казан губернасында рус булмаган халыкларны, шул исәптән татарларны көчләп христианлаштыру, башка җирләргә күчереп утырту, мәчетләрне һәм мәҗүси гыйбадәт корылмалары җимертү буенча колачлы эш алып барыла. 1749 елгы янгыннан соң Татар бистәсе халкы да шундый ук күченүгә дучар ителә, алар биләгән территориянең бер өлешендә Яңа чукындырылганнар бистәсе барлыкка килә. Куылган татарлар Поповка авылының сазлыклы җирләрендә Яңа Татар бистәсен нигезли.

Казан тарихының мөһим этабы Россия императрицасы Екатерина II исеме белән бәйле. 1767 елда шәһәргә килгәч, ул: «Бу шәһәр, һичшиксез, Россиядә Мәскәүдән кала икенче шәһәр... Казанның бөек дәүләт башкаласы булганлыгы бөтен нәрсәдә чагыла», — дип язып калдыра. Мөселман руханилары делегациясен кабул итеп, ике мәчет төзергә рөхсәт бирә. Аның әмере белән 1781 елда Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы булдырыла, соңрак, 1785 елгы «Шәһәрләр грамотасы»на нигезләнеп, шәһәр башлыгы җитәкчелегендә 6 гласныйдан торган шәһәр думасы оештырыла.

18 йөзнең 2 нче яртысында Казан Россия империясенең иң эре эчке һәм тышкы сәүдә үзәкләренең берсенә әверелә. Себер, Казакъстан, Урта Азия ханлыклары, Иран, Кытай белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә төп рольне уйный. Читкә корабльләр ясауга яраклы агач материаллары, бал, балавыз, терлек мае, постау, киндер, комач, юфть һәм башка күн әйберләр чыгарыла. Казан бистәләренең йомышлы татарлары сәүдә эшчәнлеген киң җәелдерәләр. Тышкы сәүдәдә Көнчыгыш илләре белән тыгыз икътисади элемтәдә торучы сәүдәгәрләр Апанаевлар, Әпсәләмовлар, Даутовлар, Мәмәтовлар, Шаһморатовлар, Юнысовлар һ.б. мөһим роль уйный. Әлеге чорда Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә нәфис һөнәрчелек яңадан торгызыла башлый, һәм татар гамәли бизәлеш сәнгатенең каюлы күн, укалап чигү, зәргәрчелек, ташка уеп бизәк ясау кебек төрләре үсеш ала. 1840 елларда, һөнәрчеләрнең остаханәләре белән берәттән, фабрика тибындагы предприятиеләр күренә башлый, алар күннән каюлы читекләр тегә. 1797 елгы мәгълүматларга караганда, шәһәрдә 676 рус һәм 595 татар сәүдәгәре исәпләнә. Төп сәүдә үзәге булып 776 таш һәм агач кибетләре булган Гостиный двор санала. Зур ярминкәләр үткәрелә, даими ба-



Иске Татар бистәсе. 19 йөз ахыры.

зарлар эшли (кара: *Печән базары*). 1774 елның июлендә Казанны Е.И.Пугачёв гаскәрләре яулап ала, шәһәр икътисадына һәм эчке инфраструктурасына зур зыян килә: янгында 2200 ләп йорт, Гостиный двор һәм 10 нан артык завод юкка чыга.

19 йөзнең 1 нче яртысында Казан тагын да зурая төшә, халык саны 1830–1859 елларда 43,9 меңнән 60,6 меңгә җитә. Тире эшкәртү, сабын-шәм кайнату, киҗе-мамык тукыма тукуда капиталистик җитештерү төре зур үсеш ала, һәм монда татар эшмәкәрләренең дә роле зур була. Кама (1817) һәм Иделдә (1820) пароходлар йөри башлау Казанның транзит сәүдә үзәге буларак дәрәҗәсен күтәрә. 19 йөзнең 50 нче елларына шәһәрдә буксир һәм пассажирлар суднолары төзү һәм аларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче берничә сәүдә ширкәте була. Кредит учреждениеләре һәм банкларның ачылуы сәүдә үсешенә этәргеч бирә. Шәһәр халкы сәүдәгәрләр, мещан, һөнәрче, крестьян, руханилар, хәрби һ.б. катлаулардан гыйбарәт була.

1860–1870 еллардагы буржуаз реформалар белән бәйле рәвештә, Казанның административ роле дә үсә. Ул үз губернасы мәйданыннан шактый зуррак булган округларның башында тора. 20 йөз башында Казан хәрби округына — 10 губерна һәм 2 өлкә, су юллары округына — 11, уку-укыту округына — 6, почта-телеграфка — 2, мәхкәмә округына 7 губерна керә. Шәһәрдә дәүләт учреждениеләрендә эшләүче 1700 чиновник һәм хезмәткәр, хәрби идарәдәге 700 дән артык генерал, өлкән штаб офицерлары һәм чиновниклар, Казан уку-укыту округының 800 дән артык укытучысы һәм педагогы яши.



Мокрый бистәсе. 1900 ел.

19 йөздә Казанның йөзе шактый үзгәрә. 1850 елларга шәһәрдә дворяннар, сәүдәгәрләр яши торган районнар, татар бистәләре, шәһәр читендәге эшче районнары формалаша. 1890 елларда Казанда 237 урам һәм тыкрык, 5 меңгә якын торак йорт исәпләнә. 1829 елдан шәһәрнең урам һәм мәйданнарына таш җәю эшенә керешелә. 1840 елдан урамнар кичен даими яктыртыла башлый, 1860 еллар башында фонарьлардагы киндер мае керосин белән алыштырыла. 1872 елда — газ, 1896 елда электр белән яктыртуга күчелә. 1874 елда суүткәргеч кертелә. 1875 елдан шәһәрдә атлы тимер юл («конка») эшли, 1899 елдан беренче электр трамвае йөри башлый. Казанда эчке су транспорты да була, 1868 елдан җәйләрен Кабан күлендә даими рәвештә пароходлар йөреп тора. Элемтә чараларында да сизелерлек үсеш күзәтелә: 1859 елда 1 нче телеграф станциясе файдаланууга тапшырыла, 1868 елда Казан — Мәскәү линиясе эшли башлый, 1866 елда шәһәр почтасына нигез салына, 1881 елда 1 нче телефон линиясе сафка баса, 1888 елда шәһәр телефон станциясе ачыла. Ләкин 20 йөз башына кадәр Казанның, башлыча, таза тормышлы халык яшәгән үзәк өлеше генә төзекләндерелә.

19 йөздә Казан мәгариф үзәкләренең берсенә әверелә. 1804 елда Казан университетына нигез салына. Ул 1814 елга кадәр Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе җирлегендә эшли.

1818 елдан — Казан руханилар семинариясе, 1835 елдан — Икенче ир балалар гимназиясе, 1842 елдан — Руханилар академиясе, 1859 елдан — Беренче кыз балалар гимназиясе, 1864 елдан — Җир эшләре училищесы, 1866 елдан — Земство фельдшерлык мәктәбе, 1873 елдан — Ветеринария институты, 1876 елдан — Укытучылар институты һәм Татар укытучылар мәктәбе, 1895 елдан — Сәнгать мәктәбе, 1897 елдан — Сәнәгать училищесы һәм башка югары һәм урта белем бирүче уку йортлары эшли башлый.

18 йөзнең 2 нче яртысыннан, татар бистәләрендә мәчетләр төзүдән тыюлар алынгач, 19 йөзнең 1 нче чирегендә Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә 4 таш мәчет: Унберенче (1801), Галиев, Иске таш, Зәңгәр мәчетләр төзелә; 1845 елда Печән базарында Печән базары мәчете, соңрак Солтан, Борнай, Әҗем, Кызыл мәчетләр барлыкка килә.

Казан Россиядә ислам динен укытуның иң зур үзәгенә әверелә. Күпчелек мәчетләр каршында Ахун (1770), Апанай (1780), Әмирхан (1780) һ.б. мәдрәсәләр ачыла. Мөселман уку йортларында күренекле дин галимнәре Шиһабетдин *Мәрҗани*, Ибраһим Хуҗаш, Мөхәммәдйосыф Сәгыйтов, Мөхәммәткәрим Мөхәммәтрәхимов, Габдельмәннан Рахманколый укыта, атаклы җәмәгать һәм мәдәният эшлеклеләре Каюм Насыйри, Фатих *Әмирхан*, Гаяз *Исхакый*, Муса Бигиев, Галиәсгар Камал, Мөхәммәт *Гали* һәм башкалар укый. 19 йөзнең соңгы чирегендә күп кенә ислам уку йортлары яңа ысуллар кулланып укытуга керешә, Галимҗан Баруди җитәкчелегендәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе дини һәм дөньяви фәннәрне югары дәрәҗәдә укыта торган иң зур ислам уку йортына әйләнә.

Каюм Насыйриның 60 елдан артык гомере Казан белән бәйле. Башлангыч белемне Югары Шырдан (хәзер *Кече Шырдан*) авылында әтисеннән алганнан соң, 1841 елда бишенче мәхәллә мәчете имамы Әхмәт бине Сәгыйть *әш-Шырдани* тәкъдиме белән Казанга килә һәм укуын *Касыймия* мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Җамал *Вәлиди*: «...Касыймия мәдрәсәсе реформаларга кадәрге мәдрәсәләр арасында иң беренче урын алып торды, анда иң күренекле мөдәррисләр генә хезмәт итте», — дип яза. Бер үк вакытта К.Насыйри үзлегеннән рус телен өйрәнә. Мәдрәсәне 1855 елда тәмамлаганнан соң, шәркыятьче галим Г.С.*Саблуков* ярдәме белән христиан руханилары һәм миссионерлары әзерли торган *Казан өяз руханилар училищесына* татар теле укытучысы булып урнаша, аннары әлеге уку йортының дәвамы булган *Казан руханилар семинариясендә* мөгаллим була. Руханилар семинариясендә эшләгән 1860 елларда Казан университетына ирекле тыңлаучы буларак лекцияләргә йөри. Анда, рус педагоглары һәм профессорлары И.Ф.*Готвальд*, Н.И.Ильминский, Н.Ф.*Катанов*, М.Мәхмүдов, В.В.*Радлов*, Г.С.Саблуков һәм башкалар белән белән тыгыз элемтәгә кереп, алар ярдәмендә рус телен һәм башка фәннәрне өйрәнүне дәвам итә, белгәннәрен камилләштерә. 1871 елда В.В.Радлов тәкъдиме белән Казанда башлан-



Печән базары. 1890 еллар.

гыч мәктәп (кара: *Рус-татар мәктәбе*) оештыра һәм анда татар балаларын укыта. Бу вакытта ул, үзе язганча, Сәгъди Яхин фатирында яши һәм дүрт-биш бала укыта. Сая Ибрай номерына күчкәч тә өч шәкерте була. Закир хәзрәт мәхәлләсендәге, исеме Балан Шаһи дип билгеле кеше йортында урнашкан рус-татар мәктәбендә белем бирә. 1872 елның февраль башына кадәр тиешле урын таба алмый йөргәннән соң, ниһаять, Мокрый урамындагы бер кабак өстендә фатир алып, унлап бала укыта башлый. Аннары килешү нигезендә икенче гильдия сәүдәгәр Шаһиәхмәт Салихов тарафыннан Захарьевская урамында төзеттерелгән ике катлы агач йорттан вакытлыча урын ала һәм егерме-егерме биш балага дәрес бирә. Әмма эшләре уңай гына бармый. Төрле яктан һәрдаим куркытулар булып тора, хакимияткә шикаятьләр бирелә. Җәй узгач, шул ук урамдагы икенче бер фатирга күченә, анда утызлап ир бала туплап укыта. Ләкин, кайбер мәгълүматлар буенча, рус-татар мәктәбе өчен В.В.Радлов тәкъдим иткән укыту ысулы белән килешмичә, 1876 елда аннан китә. Казан татар укытучылар мәктәбенең беренче инспекторы М.Мәхмүдов чакыруы буенча К.Насыйри 1876 елдан шушы уку йортында эшли башлый (1925 елда әлеге уку йортының дәвамчысы — Казан татар педагогия техникумына К.Насыйри исеме бирелә; кара: *Гыйльми үзәк*).



Апанай мәчете. 1880 еллар.

Мәктәптә укытуы турында «Казан шәһәрендә мөселман балалары урысча укый торган мәдрәсәнең иптидасы» (1876) дигән кулъязма хезмәтендә К.Насыйри Казанда татар балаларын русча укыту өчен мәктәп ачу тарихын яза. «Әлбәттә, мөмкин булмаган эш юк, шаять мин моны җаена китермен» дип, чын күңелдән ышанып эшкә керешә. Шәһәр буйлап фатир эзли, әмма «татар балаларына рус теле укытам» дип әйтүенә каршы йорт хуҗаларыннан тискәре җавап ала. Мокрый урамында урын тапса да, аны түбәнге катта кабак, күрше бүлмәләрдәге итекче-кәвешчеләрнең эчеп-исереп әрләшүләре, уртак ишегалдындагы күрше йортта — сыра заводы, арттарак урнашканында «кызлар ханәсе» булу, бу бозык мохиттә балаларның әдәпсез сүзләр ишетүләре борчый. Мәгърифәтчене балалар укытканы өчен полициягә дә чакыралар, хәтта Казаннан куу турында да сүзләр кузгала. Ләкин ул үз халкына, яшь буынга тугрылыклы булып кала, сайлаган юлын алга таба дәвам итә.

1879 елдан башлап, К.Насыйри, рәсми хезмәттә тормыйча, иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый. Бу чорда ул Казан университеты һәм аның галимнәре белән фәнни-иҗади элемтәләрен ныгыта. 1885 елда университет каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең* гыйльми әгъзасы итеп сайлана һәм аның җыентыгында үз хезмәтләрен рус телендә бастыра башлый. Бер үк вакытта К.Насыйри тарафыннан төзелгән календарьлар (кара: *Каюм Насыйри календарьлары*) һәм хезмәтләре *Казан император университеты басмаханәсендә* һәм башка шәһәр басмаханәләрендә нәшер ителә.

К.Насыйриның бу чорда хосусый рәвештә дәресләр бирүе, үтенеч белән мөрәҗәгать иткән кешеләргә төрле документлар язарга булышуы, китап сәүдәсе һәм кайбер башка эшләр белән шөгыльләнүе дә мәгълүм (кара: *Вакытлы матбугат*). Ул Казан тарихын өйрәнә, аңа караган риваятьләрне һәм башка материалларны туплый. Мәсәлән, аның 1881 елгы календаренда Казан шәһәре төзелү турында өч ривая ть (урын сайлау, кальга нигезенә эт күмеп калдырылу, урынны еланнардан арындыру), ханнарның исемнәре китерелә, Казанның рус гаскәрләре тарафыннан яулап алынуы, шәһәрне рус яуларыннан саклап сугышу, шулай ук Арча кыры, Постаучылар (Сукно), Җиләкле (Ягодный), Бишбалта бистәләре тарихы, Казандагы янгыннар турында бәян ителә. 1882 елгы календаренда Казанның борынгы кальгасының имән бүрәнәләрдән салынуы, уникә капкасы һәм руслар тарафыннан яулап алынганнан соң төзелгән таш кальгадан зуррак булганлыгы, Сөембикә манарасы һәм аның төзелү тарихы, рус яулап алуыннан соң татарларның шәһәрдән куылуы һәм Кабан күле буена урнашулары, анда Касыйм шәех исемле изге затның чишмә табуы, төрле хасталардан котылу өчен аның рухына дога кылулар хакында хәбәр ителә.



Воскресенское урамы. 1880 еллар.

К.Насыйри Казан турында: «Матур, яхшы төзелгән шәһәр. Кабан күле һәм Болак Казанны урталай бүлә. Алардан көньяктарак мөселман корылмалары урнашкан. Алар Казанның Бишбалта һәм Яңа Татар бистәләрендә, дары заводы янында да бар. Бу территориядә ундүрт мәчет бар. Һәр мәчет янында зур мәдрәсә бар. Мөселманнарның «Печан базары» — Печән базары дип аталган үз мәйданы бар. Аны ике йөзгә якын кибет уратып алган. Аларда сәүдәне мөселманнар алып бара. Иң әйдәп баручы товар — мануфактура, чәй, шикәр һәм ашаган һәм эчкән бөтен нәрсә. Һөнәрчеләр бүрек, читек, кәвеш һәм башка һөнәр әйберләре белән сату итәләр. Ир-ат һәм хатын-кыз аяк киеме генә дә Казанда елына 250 мең сумлык эшләнә, һәм болар барысы да мөселман осталары эше. Казанда хатын-кызлар арасында башлыча түбәтәй, такыя, калфак ясаучы осталар күп. Казанда гына да бер елда 600 меңнән артык баш киеме тегәләр. Ел саен биредә 500 меңгә якын китап, шул исәптән Коръән дә басыла. Мөселманнарның үз сабын кайнату, сукно, шулай ук шәм заводлары бар. Казан сабыны элек-электән дан тота һәм бөтен кеше тарафыннан мактала. Казан үсә, елдан-ел арта. Илленче еллар календаре буенча, шәһәрдә 45 мең кеше булган, ә хәзер аларның саны 81–82 мең тирәсе. Атнада Казанда өч зур базар була — дүшәмбе, чәршәмбе һәм җомга көннәрендә. Базарлар уза торган зур мәйданнар да өчәү: печән, балык һәм икмәк базары. Базар көннәрендә һәркайдан Казанга мал-мөл-

кәт агыла, аның очы-кырые юк. Һәм әле беркем дә үз товарын кире алып кайтмаган — кайчакта кертелгән әйбер җитәрлек түгел. Һәм иң зур җанлану — май аенда Болакта, анда ел саен Ташаяк язгы ярминкәсе уза», — дип бәян итә.

Казанда үз өе булмаганлыктан, К.Насыйригa еш кына яшәү урыннарын алыштырып торырга туры килә (кара: *Каюм Насыйри яшәгән йортлар*). Әлеге торакларның күбесе бүгенге көнгә кадәр сакланмаган, янгын вакытында яки җимерелеп юкка чыккан. Вафаты алдыннан яшәгән йортта (янгыннан соң элекке урынында торгызыла) *Каюм Насыйри музее* ачыла, аның янында К.Насыйри исемендәге *Сиксәненче мәктәп* урнашкан. Шәһәрнең тарихи Иске Татар бистәсенең үзәк урамы Каюм Насыйри исемен йөртә (кара: *Каюм Насыйри урамы*).

К.Насыйриның күп китаплары һәм кулъязмалары хәзерге Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе фондларында саклана (кара: *Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге*). Шулай ук университетта *Каюм Насыйри институты* эшли.

Каюм Насыйри Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында 1902 елда җирләнә (кара: *Каюм Насыйриның вафаты*, *Каюм Насыйриның каберe*).

Әд.: Насыров К. Календарь 1881 елга. Казан, 1880; шул ук. Календарь 1882 елга. Казан, 1881; Казань: исторические районы, слободы, улицы, площади и парки: иллюстрированный энциклопедический справочник. Казань, 2021. Кн.1; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). Казань, 1994; Старая и новая Казань. Казань, 1927.

Р.В.Шәйдуллин.

КАЗА́Н ИМПЕРА́ТОР УНИВЕРСИТЕТЫ́ БАСМАХАНӘСЕ́, югары уку йорты басмаханәсе. 1809 елда Казанда ачыла. Үз керемнәре хисабына эшли. Җитәкчесе һәм җаваплы оештыручысы (фактор) турыдан-туры ректорга һәм университет идарәсенә буйсына. Ялланып эшләү һәм эш күләменнән түләү карала. Басмаханә җитәкчесе итеп университет профессорлары һәм укытучылары, факторлар сыйфатында чит ил кешеләре билгеләнә. Хезмәткәрләр саны заказларның күләменә һәм катлаулылыгына, җиһазларның җитенкелек дәрәҗәсенә бәйле була. Кадрлар басмаханәнең үзендә әзерләнә, еш кына әтиләренең һөнәрен уллары дәвам итә.

Басмаханә ачылган вакытта 2 басу, 1 фигуралар станы, 55,5 пот шрифт, шул исәптән математика, календарь билгеләре һәм цифрлары була. Алдагы 3 елда пуансоннар, матрица һәм хәреф кою җайланмасы сатып алына, 1819 елда тагын 2 стан китерелә. 1829 елда — грек һәм гарәп хәрефләренең матрицалары һәм пуансоннары, 1832 елда төрек һәм фарсы шрифтлары сатып алына. 1834 елдан шрифтларны коеп ясауга читтән заказлар кабул ителә башлый. 1835 елда ачылган гарәп һәм фарсы, төрек-татар телләре кафедралары, үз хезмәтләрен бастыру өчен, шрифтлар белән тәэмин ителәләр, 1842 елда оештырылган әрмән теле, санскрит һәм тибет теле кафедраларына хәрефләр 1843 елда алына. 1840–1870 елларда шрифтлар — Фәннәр академиясе һәм Лазарев чит телләр институты басмаханәләреннән, Берлинның сарай басмаханәсеннән, Петербургтагы Ж.Ревильон фирмасыннан, татар шрифтлары Казан хәреф кою ширкәтчесе Фәизовтан һәм башкалардан сатып алына.

1809–1818 елларда китаплар рус, татар, латин, немец, француз һәм итальян

ян телләрендә басыла. 1830 еллардан Н.И.Лобачевский тырышлыгы белән Шәрекъ телләрендә китаплар күпләп басыла башлый. Каюм Насыйри әсәрләренең күпчелеге әлеге басмаханәдә нәшер ителә, шулар арасында *«Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах»* (1860), «Гакаиде исламия мин мөәлләфат Габделкаюм Әбелхәер» (1867), *«Хисаплык, ягъни гыйльме хисап кагыйдәләре яки арифметика вә хисаплык мәсьәләләре»* (1873), *«Әбүгалисина кыйссасы димәклә мәшһүр тәхаййелатнең тәрҗемәсе»* (1881), «Рәисе әл-хөкамәи Әбүгалисина кыйссасы димәклә мәшһүр тәхаййелатнең тәрҗемәсе» (1881, 1889, 1894, 1898, 1900, 1905), *«Әхлак рисаләсе»* (1881, 1884, 1893, 1898), *«Җәваһир әл-хикәят вә әл-әсьәлә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-мәсьәлә»* (1884, 1887, 1889), *«Мохтәсар тәварих әнбия галәйһем әс-сәлам»* (1884, 1899), *«Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»* (1884), *«Кабуснамә тәрҗемәсе»* (1888, 1898), *«Утыз вәгазь»* (1888, 1904), *«Кавагыйде кыйраәте рус мәҗмугасы илле сәбыйктыр ибтида русча укырга үгрәтүче китаптыр»* (1889), *«Әхлак рисаләсе вә форузы могтәкадәт рисаләсе вә дәхи әхәдис кодсиядән мөгаззиләрдер ки»* (1890, 1901), *«Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь, ягъни ошбу китап рус тәварихыннан бер кечкенә рисаләдер ки, моталәга кылып чыккан адәмнәр тәмам рус тәварихына мәтъләг булырлар»* (1890), *«Истыйлахәте җәгърәфия»* (1890), *«Кырык вәзир кыйссасы»* (1891, 1900, 1908), «Нәмүнә яки әнмүзәҗ. Рус теленең уку кагыйдәләрен вә дәхи сарыф вә нәхү кагыйдәләрен мөштәмәл бер рисаләдер» (1891), *«Зирагать гыйлеме, ягъни икмәк вә ашлык сачмәк, вә җимеш бакчалары әхъя кылмак бәянында бер яңа фәндер»* (1892), *«Кавагыйде китабәт, ягъни тасниф вә имля кагыйдәләрен бәян кылгучы бу бер яңа фәндер ки, бер сахибе әл-фөнүн моталәга кылып мәфһүменә төшенсә ифадәи шифаһиядә вә ифадәи тәхririядә хатадан саклана белер»* (1892), *«Иршад әл-әтбихә ила истихзар әл-әтгамә ягъни кагыйдәчә тәгам хәзерләмәк бәянында бер фәндер»* (1893), *«Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт»* (1893), *«Гөлзар вә Чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек»* (1894), *«Осуле җәгърәфияи кәбир. Азия кыйтгасы»* (1894), *«Әнмүзәҗ»* (1895), *«Гыйльме һәндәсә»* (1895), *«Иҗек.* Ибтидаи сәбыйкка шөругъ кылгучы балаларга иҗек танытмак өчен бер тәҗрибәдер» (1895), «Истыйлахәт гыйльме һәндәсә, ягъни һәндәсә фәнендә бер кечерәк китаптыр ки» (1895), *«Ләһҗәи татари, ягъни татар телендә мәүҗүд булган әлфаз гали тәртип әл-хоруф һәркайсы үзә мәкамендә зикр кылынып морадифлары белән тәфсир ителде»* (1895, 1896), *«Мәҗмуг әл-әхбар»* (1895), *«Әфсанәи Гөлрох вә Камәрҗан»* (1896), *«Гакаид рисаләсе»* (1896), *«Игъланат»* (1896), *«Исерекләк заманы»* (1896), *«Кавагыйде лисане гарәб, ягъни гыйльме сарыфтан вә гыйльме нәхүдән»* (1896), «Әл-җилди сани мин осуле җәгърәфияи кәбир. Африка кыйтгасы» (1898), «Әл-җилди ә-саләсәт мин осуле Җәгърәфияи кәбир аусаф җәзирият ә-гарәб» (1899), «Хисаплык. Гыйлме хисап фәнендә мөстәкыйль бер китаптыр» (1899), *«Санаигы голфания»* (1900), *«Иршад әл-әхба ила тәгълим әлифба. Балаларны иҗеккә төшендермәк өчен гадәте кадим үзрә бер тәгълимдер»* (1901), «Һәза китаб әл-ихтисаб фи әл-фәтави лил-шәйхе Гомәр бине Мөхәммәд Гаваз әш-Шами әл-Хәнәфи рәхмәте Аллаһы Тәгалә» (1901), *«Полный русско-татарский словарь, с дополнением иностранных слов, употребляемых в русском языке*

как научные термины» (1904), *Каюм Насыйри календарьлары* (1870–1884, 1887–1893, 1895, 1896) бар.

1886 елда Казан сәнәгый күргәзмәсендә — зур көмеш медаль, 1889 елда Екатеринбург күргәзмәсендә — алтын медаль, 1890 елда Казан күргәзмәсендә мактаулы бәяләмә ала.

Әд.: Габдельганиева Г.Г. Книгоиздательская и типографская деятельность Казанского университета второй половины XIX века. Казань, 1994; Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. Казань, 1992; Парамонова Н.Б. Книгоиздательская деятельность Казанского университета в первой половине XIX века. Л., 1977.

И.Х.Хәлиуллин.

КАЗА́Н КАЛЕНДАРЕ́ 1871 нче елга. Дүртенче ел (кәбисә елыннан соң икенче ел, 365 көн). Берничә русча календарьдан тәрҗемә вә тәэлиф кылып Габделкаюм Габденнасыйр угылы басма кылдырды Ибраһим Габдерәшит угылы Абдуллинның хәраҗәтеннән [елы һәм урыны күрсәтелмәгән]. 64 бит.

Рубрикалар:

«Яңа стиль». Ел хисабы Пётр I тарафыннан урнаштырылган гражданский һәм электән килә торган чиркәүнеке дип атала. Алар яңа һәм иске стиль буларак та билгеле. Шулай ук Юлиан һәм Григориан ел исәбе дип йөртелә. Яңа стиль искесеннән 12 көн алда барган.

«Казанның [янгын сүндерү] частьларындагы галәмәтләр». Казанның кайсы [янгын сүндерү] частена караган җирдә янгын булса, шул хакта хәбәр бирү өчен часть өстенә шарлар күтәртелгән. Беренче частьта — бер, икенче частьта — янәшә 2, өченче частьта — янәшә 3, дүртенче частьта — аслы-өсле 3, бишенче частьта — янәшә 3 шар: ике читтәгесе кыскарак, уртадагысы озынрак һәм түбәндәрәк. Кич һәм төнлә шарлар урынына кызыл фонарьлар кабызылган.

«Ревизияләр һәм хәтердә тотарга тиешле бәгъзе вакыйгалар». Россиядә 1721 һәм 1858 еллар арасында уздырылган ун ревизиянең вакытлары, тарихи истәлекле еллар күрсәтелгән.

«Рамазан шәриф башы вә һәм Корбан гаете хосусында кагыйдәләр». «Узган елгы рамазанның әүвәл көненнән хисаплап дүрт көн калдырыла, бишенче көндә руза була, икенче рамазанның нәкъ әүвәл көне була. Кәбисә ел булганда туры килми, чөнки кәбисә елында бер көн артык була. Ул елда рамазан февральдән соң килгәндә 6 нчы көндә рамазан башы була. Рузага ни көн керелгән булса, шул көн Корбан гаете була».

«Русиянең башланганы». Россиянең әүвәлге бөек князе Рюриктан башлап император Александр III гә кадәр булган патшалар идарә итү еллары белән китерелгән.

«Падишаһымыз хәзрәтләренең нәселе-ыругы бәянында». Александр III һәм аның хатыны Мария Александровна, аларның балалары, оныклары, онык чыклары китерелә, туган еллары һәм ае, көне күрсәтелә.

«Почта бәянында». Кала почтасы, башка шәһәрләргә җибәрелә торган почта, почтага бирелә торган үлчәүле әйбернең бәясе, өяз шәһәрләренә җибәрелә торган почта һәм почта атларының бәясе карала.

«Телеграф бәянында». Русиядәге телеграф челтәренең озынлыгы китерелә, түләү тәртибе аңлатыла.

«Тимер юл». Россиядәге тимер юлның гомуми озынлыгы, билет бәясе (вагонның классына карап), станцияләрдә поездларның туктап тору вакытлары, тимер юл хезмәте белән ташыла торган товарларның төрләре, Түбән Новгородтан Мәскәүгә җибә-

релә торган кайбер товарлар өчен түләү хаклары бәян ителә.

«Сату итүнең правосы бәянында». Сату итүнең өч төре күрсәтелә — күмәртәләп, ваклап һәм йөреп сату. Пошлина түләнә һәм түләнми торган товарларның атамалары китерелә.

«Сәүдә пошлинасы бәянында». Шәһадәтнамәсез сатыла торган, йортта җитештерелгән товарлар күрсәтелә, һөнәр һәм сату өчен алынган таныклыкларның пошлина класслары, сату һәм һөнәр оешмасы өчен билет пошлинасы, кибеттән, лавкадан, арбадан һәм чанадан сату өчен шәһадәтнамә һәм билет, капка төбендәге һәм өйдәге кибетләрдән сату ысуллары аңлатыла.

«Үлчәүләр бәянында». Озынлык үлчәүләре: миль, чакрым, колач, аршын, чирек, карыш, фут, сажин, дюйм һ.б.; ашлык үлчәүләре: кап, батман, почык, пудаука; сату үлчәүләре: пот, кадак, лот, мыскал; аптека үлчәүләре: унция, драхма, кәренгә аңлатма бирелә.

«Нотариаль актларны ясаган нотариус иҗарәсе [бәясе]». Актларның төрләре буенча вексельләрне, килешүләрне раслаган; актлар, килешүләр ясаган һәм раслаган; күчермәләрне һәм имзаларны раслаган; ышанычнамәләр, солых язулары ясаган яки раслаган; һәртөрле кәгазьне актлар кенәгәсенә теркәгән; пенсия алучы кешенең сәламәт булуын дәлилләгән; документлар һәм һәртөрле кәгазьләрне саклауга алган; белешмә ясаган, өземтә күчереп биргән һәм башкалар өчен түләнә торган бәяләр аңлатыла.

«Яңа хөкем бәянында». Яңа хөкем буенча каралган мировой суд, мировой съезд, суд палатасы, Сенат департаменты, мировой судья турында бәян ителә.

«Мировой судья нинди эшләрне тикшерергә тиеш, аның бәянында». Акча һәм алыш-бирәш турында 500 сумга кадәр низаглы эшләрне карау, 500 сумга кадәр зыянны түләтү, берәүне рәнҗеткән, тиргәгән өчен хөкем итү, берәүнең милке ниндидер сәбәп белән кулыннан киткән булса һәм алты ай үтмәсә, аны хуҗасына кире кайтару турында хөкем итү, гаеп өчен шелтә һәм кисәтү белдерү, штраф салу (300 сумга кадәр), өч айга кулга алдыру, бер елга кадәр төрмәгә ябарга мировой судьяның хокукы барлыгы аңлатыла.

«Поверенный (кәфил) бәянында». Дәгъвачы мировой судьяга үзе барып яки башка кешене ышанычнамә белән кәфил итеп җибәрә ала. Балигъ булмаган, авыру, хөкем астындагы кеше кәфил була алмый.

«Дәгъвачының дәгъвасын исбат кыла торган эшләр бәянында». Дәгъвачының дәгъвасы гуаһлык бирү, килешү язу, ышаныч кәгазе бирү, вакыйга булган урынны карау, ант итү белән исбатлана. Дәгъвачының карендәшләре, хатыннары, авыру кеше, балигъ булмаган балалар, вазифаларыннан азат ителгән муллалар һәм поплар шаһит була алмый.

«Ответчикны вә һәм гуаһларны мировойга чакыру бәянында». Дәгъвачы белән җавап бирүче мировой судьяга бергә барса — аларның эше тоткарсыз тикшерелә. Дәгъвачы үзе генә барса, җавап һәм гуаһ бирүчеләр йомышчы яки полиция, волость идарәсе башлыгы аркылы чакыртыла. Чакыру кәгазе кешенең үз кулына, ул өйдә булмаса, хатынына яки өйдәге башка берәүгә, алар да булмаса, күршесенә тапшырыла һәм бу хакта раслама алына. Җавап һәм гуаһ бирүче кеше билгеләнгән вакытта мировой судьяга килмәсә һәм кабул итәрлек сәбәп күрсәтә алмаса, штраф салына.

«Мировой судьяда эшләр тикшерелү бәянында». Хөкемгә тарттырыл-

ган кеше гаепсез табылса, һич тоткарсыз җибәрелә. Дәгъва гаделсез булса, хөкем чыгымнары дәгъвачыдан түләтелә.

«Мировой судьяларның җыелышуы бәянында». Мировой судьяларның җыелышында, ягъни съездында соңгы дип табылган хөкем карарлары, эшне яңадан карау мәсьәләләре тикшерелә.

«Мировойда эш йөртүнең хәражәтләре бәянында». Мировой судья гуаһлык күрсәтүчеләргә түләүне юл ераклыгына карап билгели. Ул гаепле дип табылган кеше хисабыннан бирелә. Әгәр гаепле кешенең матди мөмкинлеге булмаса, акча дәүләт хисабыннан түләнә.

«Гаебенә күрә мировой судьяда бирелә торган җәзаларның бәгъзеләре бәянында». Кануннарны тиешле рәвештә үтәмәгән; полиция, волость, земство идарәсе башлыкларының сүзләрен тыңламаган; ызан һәм чик билгеләрен бозган, гыйбадәт йортларында тавыш-гауга чыгарган; ачык җирдә гыйбадәт кылганда уен-көлке белән бимаза кылган; урамда һәм базарларда кемгә дә булса кул күтәргән; җәмәгать урыннарында лаякыл исерек килеш күренгән; ялкаулыгы һәм эшлексезлеге нәтиҗәсендә йорт саен соранып йөргән; балаларын, ага-әнесенең һәм башка карендәшләренең балаларын соранып йөрергә мәҗбүр иткән; елгаларга, чишмәләргә, кануларга чүп-чар ташлаган; су ала торган җирләрдә, бәкеләрдә керләр юган, коенган, тиешле булмаган урыннарга чүп, тирес ташлаган һәм башкалар өчен гаепле кешедән штраф түләтелүе, яки аның кулга алынуы турында әйтелә.

«Окружной судлар бәянында». Округ суды мировой судлар вазифаларына карамаган эшләрне тикшерә. Вакыйга кайсы округта булса, шунда каралган. Суд присяжныйлар катнашында булган.

«Судебный палат бәянында». Суд палатасының округ суды өстеннән булган апелляция шикаятьләрен тикшерүе, аның карарын бары тик Сенат департаменты гына үзгәртә алуы бәян ителә.

«Кассационный суд бәянында». Кассация суды Сенат департаментында була һәм аның карары белән хөкем тәмам туктатыла.

«Уездный земский учреждение бәянында». Өяз земство оешмалары булып өяз земство җыелышы һәм идарәсе торганлыгы, җыелышка гласныйлар сайлануы турында әйтелә. Бу оешмаларның уртак файдага акча җыю, йортларны, юлларны төзек тоту, хәйрия һәм ярдәм итү оешмалары, халык хәстәрен күрү, фәкыйрьлеккә һәм мохтаҗлыкка каршы эш алып бару, сату-алу эшләрен киңәйтү, халыкның аң-белемен үстерү өчен тырышу, игеннәргә зарар килү очракларын алдан кисәтү һ.б. белән шөгыльләнүе бәян ителә.

«Чит илгә чыгу өчен паспорт алуның тарикы бәянында». Чит илгә чыгу өчен паспорт алуның барлык катлау вәкилләренә рөхсәт ителүе, аның губерна, кала һәм волость идарәсе башлыклары, полицмейстер тарафыннан бирелүе, шулай ук чит илгә барып була, ләкин кайтып булмый, барып һәм кайтып була торган ике төрле паспорт булуы турында аңлатыла.

«Русиядәге губерналар бәянында». Россиядәге губерналар саны, атамалары, аларда яшәүче ирләр һәм хатын-кызларның, мөселманнарның саны таблица рәвешендә китерелә.

«Акча вә һәм процентлы кәгазьләр бәянында». Алтын һәм көмеш акчаларның пробасына карап, сум һәм тиеннәрнең микъдары китерелә, кәгазь

акчаларның төсләре буенча суммалары күрсәтелә.

«Балаларны русча укыту турында». Мөселман балаларын русча укыту мәсьәләсе турында «Известия Казанской епархии» журналының 1870 елгы 18 санында, «Министерство народного просвещения» журналының 42 санында басылган материаллар тәрҗемә ителеп бирелгән.

«Духовное собрание хосусында». Диния нәзарәтенең канун һәм кагыйдәләрен бер тәртипкә салу турында «Православный вестник» журналыннан күчереп, «Казанские епархиальные известия» газетасының 24 санында басылган мәгълүматның тәрҗемәсе китерелгән.

Р.Ф.Исламов.

КАЗА́Н КАЛЕНДАРЕ́ 1872 нче елга. Икенче ел (1872 нче ел кәбисә елы булып, 366 көн килә). Габделкаюм Габденнасыйр угылы иҗат вә тасниф итеп икенче мәртәбә басма кылдырдым Казанда университет типографиясендә [1871] Ибраһим Габдерәшит угылы Абдуллинның хәражәтеннән. 80 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Русия тәварихыннан берничә сәхифә». Россия бердәм дәүләт булып оешканчы булган Полтава, Галиция, Волын, Чернигов, Смоленск, Суздаль, Новгород князьлекләре, монгол яулары турында бәян ителә.

«Мәскәү мәмләкәте». Мәскәү бөек князе Иван Калитадан башлап император Александр III гә кадәр булган патшалар идарә итү еллары белән күрсәтелгән.

«Сәгатьләрнең тәвафете [аермасы]». Россия шәһәрләрендә, төрле илләрдә көн уртасына туры килә торган сәгатьнең аермалары тасвирлана.

«Гыйнвар башы хосусында». 1890 елга кадәр гыйнвар башы, православие диненең Май [чабу] (Масленница), Кызыл йомырка (Пасха), Троица бәйрәмнәренә туры килгән көннәр күрсәтелә.

«Бәгъзе әхкәм вә канун». 1870, 1871 елларда кабул ителгән кануннар, 1871 елдан иске кәгазь акчаларның гамәлдән чыгарылуы хакында мәгълүмат китерелә.

«Русиянең җәгърәфиясеннән берничә сәхифә». Россиянең коры җирдәге һәм диңгездәге чикләре, елгалары, аларның кайсы диңгезгә коюлары, шәһәрләре хакында бәян ителә.

«Йир йөзендәге халыкларның хисабы». Календарьлардагы мәгълүматка нигезләнеп, планетадагы халыкның саны (1 335 000 000 кеше) китерелә.

«Йир йөзендә үлгән халык хисабы». Җир йөзендә һәр елда үлгән кешенең саны 339 000,0 дип күрсәтелә, бер көндә, бер минутта ничә кеше вафат булуы, уртача гомер озынлыгы әйтелә.

«Русиядә ничә төрле халык». Россиядә рус телендә сөйләшә торган халыкларның саны күрсәтелә, чит илдән кертелгән һәм Россиядән читкә чыгарылган әйберләрнең атамалары, аларның күләм микъдарлары китерелә.

«Ят мәмләкәтләр хосусында». Кайбер чит дәүләтләрнең патшалары, диннәре, яшәгән халкының, гаскәренең саны китерелә, кертелгән һәм чыгарылган товарларның күләме күрсәтелә.

«Почта бәяны». Мөһерле хат, ачык хат, бандероль, түләүсез посылка һәм кыйммәтле пакет, түләүле пакет, страхование бәясе турында бәян ителә.

«Телеграф бәяны». Телеграф аша депешалар, телеграммалар җибәрү, түләү тәртибе һәм бәясе аңлатыла.

«Мөселманнарны ант иттерүнең бәяны». Башта мулланың антның нәрсә икәнен аңлатуы, аннары ант итүче кешенең, тәһарәт алганнан соң, Коръәнгә кулын куеп, ант сүзләрен укып телдән әйтүе, кеше укый белмәсә, ант сүзләрен мулла әйткәндә кабатлап баруы турында сөйләнелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЗА́Н КАЛЕНДАРЕ́ 1873 нче елга. Өченче ел (кәбисә елының соңындагы әүвәлге ел, 365 көн). Габделкаюм Габденнасыйр угылы иҗат вә тасниф итеп өченче мәртәбә басма кылдырдым Казанда университет типографиясендә 1873. 64 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Диянәт хиссиятеннән Русиядәге халык». Мөселманнар, протестантлар, христианнар, католиклар, иске дин тарафдарлары, яһүдиләр, әрмәннәр, мәҗүсиләрнең саннары китерелә; Вятка, Воронеж, Курск, Полтава, Тамбов губерналарында туучылар саны вафат булучыларныкыннан һәрвакыт артыграк булуы әйтелә.

«Вексель формасы». Вексель формасының үрнәкләре татар һәм рус телләрендә китерелә.

«Легковой һәм ломовой ямщиклар өчен низам». Җиңел һәм йөк ташыла торган арба-чаналарның торышы, бу эштә эшләү өчен тиешле органнардан номер алу, аларның кая беркетелүе; урамда йөрү кагыйдәләрен үтәү тәртибе, кагыйдәләрне бозган очракта билгеләнгән җәза ысуллары аңлатыла.

«Легковой ямщикларның таксасы». Каланың дүрт частеннан читкә чыгу яки керү; сәгатьләп түләү, бәйрәм вакытларында эшләгән өчен бәяләр күрсәтелә.

«Ломовой ямщиклар өчен низам». Шулай ук каланың дүрт частеннан читкә чыгу, яки керү; йөкнең авырлыгына карап түләү бәяләре күрсәтелә.

«Кимиядән [химиядән] берничә сүз». Киемдәге төрле тапларны (май, балавыз, буяу, кан, бәвел, аракы, серкә) бетерү өчен матдәләр; серкә, язу карасы ясау ысуллары өйрәтелә.

«Аракы эчәргә гадәтләнгән кешеләргә бер-ике кәлимә сүз». Аракыны аш алдыннан бер рюмка гына эчүне гадәт итүнең файдалы, ә исергәнче эчүнең авырулар китереп чыгаруга сәбәп булуы аңлатыла. Шулай ук хайваннарны төрле чебен-черки, кигәвеннән саклау өчен аракы яки спирт белән сыекча ясау ысулы да өйрәтелә.



К.Насыйри. Казан календаре 1873 нче елга. Казан, 1873.

«Тыйбтан [медицинадан] берничә сүз». Бит, тән тиресен шома һәм ак итү, тирләүне, биттәге вак шадраларны, сипкелләрне, җыерчыкларны, уртлар шешкәнне бетерү, кысылганда оешкан канны тарату, йөзне йомшарту өчен дарулар ясау ысуллары китерелә.

«Сач үстерү өчен дәвалар». Чәч һәм сакалны тәртиптә тоту, чәч сирәгәйгәндә, агара башлаганда чәчне үстерү

өчен; өшегәндә, пешкәндә сөртә, сөялне бетерә торган, теш сызлаганда кулланa торган даруларны ясау ысуллары тәкъдим ителә.

Р.Ф.Исламов.

КАЗА́Н КАЛЕНДАРЕ́ 1874 нче елга. Дүртенче ел (кәбисә елыннан соң икенче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп дүртенче мәртәбә басма кылдырдым Габделкаюм Габденнасыйр угылы Мөхәммәтҗан Мифтахетдин угылының хәраҗәтеннән Казанда университет басмаханәсендә, 1874. 52 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Кайсы эшләр гласный тикшерелә, кайсы эшләр негласный тикшерелә, шуның бәянында». Чит кешеләр алдында һәм гариза белән тикшерелә торган эшләр — ачык мәхкәмә дип; гаризасыз, сүз белән һәм яшерен рәвештә тикшерелә торган эшләр — ябык мәхкәмә дип аталу турында аңлатыла.

«Хива вакыйгасы». Хива ханлыгының төзелүе, андагы тормыш рәвеше һәм Россия тарафыннан яулап алынуы, яңа тәртипләр урнаштырылуы тасвирлана.

Р.Ф.Исламов.

КАЗА́Н КАЛЕНДАРЕ́ 1875 нче елга. Бишенче ел (кәбисә елыннан соң өченче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп бишенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы Казан мещаны Шаһиәхмәт Сөләйман угылы *Биккиниевнең* хәраҗәте илән 1875 нче елда. Бу китаб Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр. 59 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Брюс ниндәен кеше булган». Чыгышы буенча шотландияле булган Я.В.Брюсның (1670–1735) хәрби һәм дәүләт эшлеклесе булганлыгы, Василий Куприянов тарафыннан Россиядә беренче мәртәбә төзелгән календарьны тикшереп бастырган өчен алга таба «Брюс календаре» дип атала башлавы турында бәян ителә.

«Государственный банклар бәянында». Биредә төп дәүләт банкының Петербургта булуы турында әйтелә һәм аның конторалары, бүлекләре булган шәһәрләрнең исемлеге китерелә.

«Русия мәмләкәтенең олуг вә баш мәхкәмәләре». Россиянең югары мәхкәмәләре итеп Дәүләт советы, Министрлар комитеты, Кавказ комитеты, Патша канцеляриясе, Гариза комиссиясе, Сенат мәхкәмәсе һәм аларның тармак бүленешләре күрсәтелә.

«Европадагы мәшһүр олуг калалар вә һәм халыкларының хисабы». Лондон, Париж, Вильно, Берлин, Петербург, Истамбул, Неаполь Европадагы зур шәһәрләр буларак белдерелә һәм шул чорда алардагы халык саны китерелә.

«Гербовой марканы истигъмаль кылуның [куллануның] тарикы [юлы]». Документларга гербовой марканы ябыштыру, аңа вакытны кую, маркаларны гамәлдән чыгару тәрипләре өйрәтелә.

«Каванине гаскәрия [Гаскәр кануннары] яки Лөзүме [тиеш] гаскәрия [Гаскәргә тиеш] уставларыннан интихаб кылынмыш [сайлап алынган] бәгъзе статьяларның бәяны». Хәрби хезмәткә чакыру (жирәбә буенча), хезмәтнең сроклары, запаска чыгарылу, коры җир һәм диңгез флоты, гаскәриләрнең хокуклары һәм моң бәйле башка мәсьәләләр карала.

«Технологиядән берничә кәлимә». Бодай, бәрәңге крахмалы, мамыктан дары, яна торган порошок, шәм, хуш исле май, лак, сургуч ясау ысуллары өйрәтелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЗА́Н КАЛЕНДАРЕ́ 1876 нчы елга. Алтынчы ел (кәбисә елы, 366 көн). Иҗат вә тасниф итеп алтынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы Мөхәммәтнәҗип Галиәкбәр угылының хәраҗәтеннән. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 24 нче нуябер 1875 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр [1875 нче елда]. 48 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Брюс календаре». Календарьда 1876 елда кыш, яз, җәй, көз айларының ничек булачагы бәян ителә.

Р.Ф.Исламов.

КАЗА́Н ӨЯЗ РУХАНИЛА́Р УЧИ́ЛИЩЕСЫ, Россия Изге Синодының гомуми идарәсе карамагындагы башлангыч белем бирү дини уку йорты. 1818 елда Казанда балаларны православие чиркәвенә хезмәт итүгә әзерләү өчен оештырыла.



Казан өяз руханилар училищесы. 19 йөзнең 2 нче яртысы.

Училище 4 сыйныфтан торган. Анда төрле катламнан, әмма башлыча рухани гаиләләреннән булган ир балалар белем алган. Чиркәү хезмәткәрләре балалары бушлай укыганнар, башка катлау балалары өчен уку түләүле булган. Әлеге уку йорты үзендә тәрбияләнүчеләрне дини семинариягә керергә әзерләгән. Эшчәнлеге Казан епархиясе руханилары җыйган акча хисабына алып барылган.

1818 елдан, уку йорты ачылу белән үк, аның уку-укыту программасына татар теле дәресләре кертелә, аларны 1824 елга кадәр миссионер А.А.Троянский укыта. 1855 елда училище ректоры протоиерей Ираклий Лепоринский тәкъдиме белән уку йортында татар теле һәм сөйләм дәресләрен укытырга Каюм Насыйри чакырыла. Әлеге уку йортында ул 1871 елга кадәр, *рус-татар мәктәбенә* киткәнче, православие динендәге балаларга татар теле грамматикасын укыта, аларның татарча сөйләм телен камилләштерә. Бер үк вакытта ул *Казан руханилар семинариясендә* татар теле укытучысы булып эшли.

Әд.: Кара: *Казан руханилар семинариясе.*

Г.Р.Дәүләтьянова.

КАЗА́Н РУХАНИЛА́Р СЕМИНА́РИЯСЕ, урта дини белем бирүче Рус Православие чиркәве уку йорты. 1723 елда Казан архиерей славян-латин мәктәбе буларак ачыла; 1733 елда Казан руханилар семинариясе, 1798 елда Казан руханилар академиясе итеп үзгәртелә, 1818 елда яңадан семинария буларак торгызыла. 1868 елга кадәр дини катлау балалары гына кабул ителә, соңрак та укучыларның күп өлешен шулар тәшкил итә.

Дини мәктәпләр реформасы нигезендә 1808 елда уку-укыту программалары гомуми белем бирү характерында була, 1842 елгы реформа барышында алар тагын да ныгытыла. 1821 елдан семинариядә татар теле укытыла башлый. Бу эшне татар теле белгече, татар теле грамматикасы һәм сүзлекләре авторы А.А.Троянский башлап җибәрә. Ул 1824 елга (вафатына) кадәр атнага берәр сәгатьле өч дәрес укыта. 1849 елда аңа алмашка Казан

руханилар академиясе профессоры Г.С.*Саблуков* килә, тик әлеге өлкәдә зур уңышларга ирешә алмый. 19 йөзнең 1 нче яртысында мөселманнар арасында миссионерлык эшен алып бару өчен Казан епархиясенә татар телен яхшы белүче руханилар җитенкерәмәү сәбәпле, Саблуков тәкъдиме белән татар һәм гарәп телләрен укыту программалары берләштерелә, уку сәгатьләре арттырыла, семинариядә укучылар ике төркемгә бүленә һәм 1852 елда гамәли татар теле классы ачыла. Аның беренче укытучысы итеп күренекле татар теле белгече Хәйрулла Әйбәтов раслана.



Казан руханилар семинариясе. 19 йөз уртасы.

1855 елда Саблуков тәкъдиме белән семинариянең әлеге сыйныфына «*Касыймия*» мәдрәсәсен тәмамлаган 30 яшьлек Каюм Насыйри чакырыла. Семинариядә ул татар теле грамматикасын, татар телендә Евангелиене һәм сөйләм телен укыта. Насыйриның укучылары татар сүзләренең килешләр белән төрләнешен һәм фигыльнең заманнарын яхшы үзләштерәләр, шулай ук аларны грамматик җәһәттә тикшерергә өйрәнәләр. Насыйри әлеге уку йортында 1871 елга кадәр, үзе оештырган *рус-татар мәктәбенә* киткәнче эшли, семинария укучыларына белем бирүгә зур көч куя. Аның аеруча сәләтле укучылары арасында П.П.*Масловский* да була.

Әд.: Маһиярова З.М. Каюм Насыйриның Казан «Духовная семинариясе»ндә укыту тәҗрибәсенең яңа белем бирүдә әһәмияте» // Вторая Международная научно-практическая конференция «Насыйри укулары» — «Насыровские чтения». Казан, 2023; Благовещенский А. История Казанской духовной семинарии с восемью низшими училищами за XVIII–XIX вв. Казань, 1881; Покровский И.М. К столетию кафедры татарского языка в духовно-учебных заведениях г. Казани (1800–1900 гг.). Казань, 1900; Рыбочкин С.А. Преподавание инородческих языков в начальных и средних духовных учебных заведениях Казанской епархии в XIX веке // Труды Белгородской Православной Духовной семинарии (с миссионерской направленностью): Сборник научных трудов. Белгород, 2021. Вып. XI.

Г.Р.Дәүләтьянова.

КАЗА́Н ТАТА́Р УКЫТУЧЫЛА́Р МӘКТӘБЕ́, махсус дәүләт уку йорты. 1876 елда Казан уку-укыту округының татар мәктәпләре инспекторы В.В.*Радлов* башлангычында ачыла. Рус-татар мәктәпләренә укытучылар әзерләү өчен оештырыла. Эшчәнлеге Россия хөкүмәтенең Татар укытучылар мәктәпләре турындагы 1872 ел 27 март нигезләмәсе белән билгеләнә.

Уку йортына *рус-татар мәктәпләрендә*, мәдрәсәләр каршындагы рус сыйныфларында рус теленнән башлангыч белем алган яшүсмерләр кабул ителә. Алар барысы да диярлек дәүләт хисабына укый, тулай торакта яши, туклану, форма киеме белән тәэмин ителә. 1876 елда расланган уку-укыту планы буенча, уку срогы 4 ел була. Бу тәртип 40 ел дәвамында үзгәрми. Төп фәннәргә — рус теле, педагогика һәм дидактика, педагогик практикага зур урын бирелә, соңгысы

мәктәп каршындагы үрнәк рус-татар мәктәпләрендә уздырыла. Математика, тарих, география, табигать белеме, рәсем дәресләре шәһәр училищелары программасы буенча укытыла. Ислам дине тәгълиматын өйрәнүгә күп сәгатьләр бирелә. Аңардан кала, барлык фәннәр буенча дәресләр рус телендә алып барыла. Беренче унъеллыкта мәктәпкә ел саен 10–15 кеше кабул ителә, 20 йөз башына бу күрсәткеч 20 кешегә җитә.

Эшли башлавының беренче елларыннан ук мәктәп югары дәрәҗәдәге уку йортына әверелә, аны тәмамлаучылар рус телендә иркен сөйләшә торган квалификацияле белгечләр була. Рус телен барлык инспекторлар, шулай ук атаклы педагоглар А.И.Анастасиев, В.А.Богородицкий, М.А.Васильев укыта. Укучылар шулай ук мөселман дин белемен дә өйрәнәләр. Аның беренче укытучысы Ш.*Мәржани* була. Аны 1885–1909 елларда Т.Г.Яхин алыштыра. Табигать белемен 1880–1906 елларда И.В.*Терегулов* укыта. Аның башлангычында мәктәпкә физика, химия, биология буенча иң яхшы күрсәтмә уку-укыту ярдәмлекләре алына. Рәсем дәресләрен 1885–1917 елларда татарлардан иң беренче дипломлы рәссам Ш.Ә.Таһиров алып бара, тарих, география, математиканы университет белеме булган тәҗрибәле укытучылар, шул исәптән П.В.Траубенберг, А.В.Васильев укыта.

Каюм Насыйри 1876–1879 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә татар теле буенча гамәли дәресләр алып бара. Биредә эшләгән чорда ул күп кенә күренекле зыялылар, галимнәр белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыра. Аерым алганда, Шәрекъ телләре белгече, партия эшлеклесе Галимҗан Акчурин В.В.Радловның Каюм Насыйрины, Шаһбазгәрәй *Әхмәровны,* Ибраһим *Терегуловны* татар укытучылар мәктәбенә укыту эшенә чакыруы, аларның 7–8 ел үзара аралашуы хакында: «Радлов җәнапләренең 50 еллык бәйрәм мөнәсәбәт илә язылмыш тәрҗемәи хәлендә язучы әфәнде (Л.Штернберг) Радлов Казанда торганда дарелмөгаллимин өчен бик кыенлык илә 3 мөселманны үзенә мөгаллимлеккә табып алды. Берсе мәшһүр, татар китаплары, лөгать китаплары вә тәкъвимнамәләр (географик координатларны, шулай ук йолдызларның хәрәкәт юлларын күрсәтә торган таблица) нашире Габделкаюм Насыйри, 2 нчесе дарелфөнүнне әкмәл итмеш Әхмәров (соңыннан ул мәктәптә мөдир дә булмыш), 3 нчесе голүме табигыят (табигать фәннәре) укытыр өчен хәйванат дуктыры (ветеринария табибы) Терегулов җәнапләре. Димәк, тәрҗемәи язучының сүзеннән: Радлов җәнапләре вә бу язылган Әхмәров илә Терегулов җәнапләре Насыйри илә 7, 8 ел катнашканнар, белешкәннәр», — дип хәбәр итә (кара: *Истәлекләр*).

Мәктәп татарлар арасында рус теленең таралуында әһәмиятле роль уйный. Аны тәмамлаучылар һәм аның укытучылары төп дәреслекләрнең авторлары булалар, укыту методикасын төзиләр, рус-татар училищеларында гына түгел, атаклы мәдрәсәләрдә дә укыталар, яңа типтагы татар мәктәбе формалашуда мөһим роль уйныйлар. Мәктәптә күп кенә милли хәрәкәт җитәкчеләре, хәрби җитәкчеләр, галимнәр, мәгърифәтчеләр һәм педагоглар, язучылар, мәдәният эшлеклеләре белем ала. Мәктәпне тәмамлаучылар рус-татар училищеларында гына түгел, ә иң яхшы мәдрәсәләрдә дә («Бубби», «Мөхәммәдия», «Касыймия», «Госмания» һ.б.) укыталар, яңа типтагы татар мәктәбе формалашуда мөһим роль уйныйлар.

1917 елда — Татар укытучылар семинариясе, 1919 елда — педагогик

курслар итеп үзгәртелә, 1921 елда аның җирлегендә Казан татар педагогия техникумы оештырыла. 1876 елдан мәктәп Бутягин йортында урнаша (хәзер Тукай урамы), 19 йөз башы архитектура истәлеге.

Мәктәпнең инспекторлары: М.*Мәхмүдов* (1876–1881 еллар), Ш.И.Әхмәров (1881–1900 еллар), М.Н.Пинегин (1900–1907 еллар) һ.б.; попечительләре: сәүдәгәрләр М.И.Галиев, М.Г.Мусин, М.М.Галикәев, юрист С.Ш.Алкин. Алар мәктәпкә зур матди ярдәм күрсәтәләр.

Әд.: Гайнетдинов М.Г. Татар башлангыч мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү (XIX–XX гасырлар). Казан, 2002; Исхакова Р.Р. Казанская татарская учительская школа и её роль в формировании и становлении национального образования. Казань, 2002; Траубенберг П.В. Татарская учительская школа в Казани. Казань, 1980; Хакимов Х.Х. Роль Казанской татарской учительской школы в развитии и распространении прогрессивной педагогической мысли среди татар // Учёные записки Казанского педагогического института. 1972. Вып. 105.

И.Х.Хәлиуллин.

«КАЗА́Н ТАТАРЛАРЫНЫ́Ң ТОРМЫШЫНДА́ ИСЛА́М ДИНЕ́ ЙОГЫНТЫСЫННА́Н ТЫШ БАРЛЫККА́ КИЛГӘ́Н ЫШАНУЛА́Р ҺӘМ ГОРЕ́Ф-ГАДӘТЛӘ́Р», кара: «*Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства*».

«КАЗА́Н ТАТАРЛАРЫНЫ́Ң ХАЛЫ́К ӘДӘБИЯТЫ́ ҮРНӘКЛӘРЕ́», кара: «*Образцы народной литературы казанских татар*».

КАЗЫЙХА́НОВ Вил Суфиян улы (24.09.1939, Башкортстанның Дүртөйле районы Дүртөйле авылы – 01.10.2012, Дүртөйле), педагог, төбәкне өйрәнүче, язучы-шагыйрь, журналист, Башкортстан АССРның (1977), РФнең атказанган укытучысы (1993), РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы (1975). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2002).



В.С.Казыйханов

Дүртөйленең 1 нче мәктәбен (1956), Башкорт университетының филология факультетын (1962) тәмамлый. 1962–1963 елларда Иске Солтанбәк сигезьеллык мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1963 елдан КПССның Дүртөйле район комитеты инструкторы, 1964 елдан ВЛКСМның район комитеты беренче секретаре вазифаларын башкара. 1966–1994 елларда 3 нче урта мәктәп директоры булып эшли. 1994 елдан Татарстанның Чаллы шәһәрендә Өстәмә белем бирү институтының иҗади үсеш технологиясе лабораториясе методисты, 2002–2007 елларда тәрбия һәм өстәмә белем бирү кафедрасы өлкән укытучысы. 2007–2009 елларда Башкорт педагогия университетының психодидактика һәм әхлак белеме фәнни-тикшеренү лабораториясендә тәрбия бүлеге мөдире була.

Хезмәтләре үстерелешле укыту методикасы һәм әхлак тәрбиясе мәсьәләләренә карый. Ул шулай ук мәкаләләр һәм китаплар авторы.

2019 елда аңа туган ягы Дүртөйледә истәлек тактасы ачыла һәм бер урамга аның исеме бирелә.

Хезм.: Математика. 1 нче сыйныф: Укытучылар өчен дәрес эшкәртмәләре. Яр Чаллы, 1995 (автордаш); Математика. 2 нче

сыйныф: Уку-укыту әсбабы. Яр Чаллы, 1996 (автордаш); Математика. 3 нче сыйныф: Уку-укыту әсбабы. Яр Чаллы, 1997 (автордаш); Әхлак белеме: Хрестоматия. Яр Чаллы, 1997; Уроки духовности. М., 2005.

Әд.: Җамалетдинова Ф. Мәктәп хуҗасы — укучымы, яки Үстерелешле укыту турында // Фән һәм мәктәп. 1997. № 9; Нуретдинова И. Гомеремне балаларга багышладым // Фән һәм мәктәп. 2004. № 10.

Ф.С.Гыйниятуллина.

КАЛЕНДА́РЬ 1877 нче елга. Җиденче ел (кәбисә елы артындагы ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп җиденче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1876 нчы елда. 56 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Казан губернасындагы мөселманнар өязе-өязе белән». Казан губернасындагы Казан, Зөя, Чабаксар, Чуел [Цивильск], Чар [Царёво-Кокшайск], Мамадыш, Чистай, Лаеш, Спасс, Тәтеш өязләрендә ир һәм хатын-кызлар, никах, туган һәм вафат булганнар (ирләр, хатын-кызлар), авылларның саннары китерелә.

«Уфа губернасындагы мөселманнар иҗмалән [кыскача]». Уфа губернасында 1875 һәм 1876 елларда туган, вафат булган ирләр һәм хатын-кызлар, никахлар һәм аерулышулар саны күрсәтелә.

«Җәгърәфиядән». Тулаем Җир шарында, аерым алганда Европа, Азия, Африка, Америка, Австралиядә яшәүче халыклар саны китерелә; «Европадагы мәшһүр мәмләкәтләр ошбулардыр». Биредә Англия, Дания, Швеция, Норвегия, Германия, Австрия, Нидерланд, Бельгия, Франция, Италия, Испания, Португалия, Греция, Русия дәүләтләре башкалалары һәм бу илләрдәге халык саны күрсәтелә; «Азиядәге мәшһүр мәмләкәтләр ошбулардыр». Һиндстан, Госманлы, Кытай, Монголия-Тибет, Кашгар, Бирма, Сиам, Аннам, Биго, Бутан, Далбум, Кашмир, Балти, Ладак, Бохара, Кызылбаш, Әфганстан дәүләтләре башкалалары һәм алардагы халыкның саны күрсәтелә; «Африкадагы мәшһүр мәмләкәтләр ошбулардыр». Мисыр, Хәбәшстан (Эфиопия), Триполи, Тунис, Алжир, Марокко, Судан, Гвинея, Занзибар һәм башка дәүләтләр, кайберләренең башкалалары һәм алардагы халыкның саны күрсәтелә.

«Некролог вә һәм кабер ташлары». Габденнасыйр Курсави, Габдерәхим Утыз Имәнинең кыскача биографияләре, башкарган эшләре бәян ителә, Чуел өязе Бакырчы авылы зиратындагы Мөхәммәд Чәләбинең кабер ташы, һәм аның тормышы хакында сөйләнә.

«Мохтәрәгат әүвәлия [Беренче уйлап табылганнар]». Җир йөзендә иң беренче мәртәбә уйлап табылган әйберләр еллары, илләре, шәһәрләре белән күрсәтелә.


Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1878 нче елга. Сигезенче ел (кәбисә елы артындагы икенче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп сигезенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басмасына рөхсәт бирелде 3 нче үктәбер 1877 нче елда. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1877 нче елда. 32 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Кыска тәварих вә һәм кабер ташлары». Татар укымышлылары Ишни-

яз бине Ширнияз әл-Харәзми әл-Үргәнҗи, Сәгыйть бине Әхмәт әш-Шырдани (1741–1831), Габдерәхим Утыз Имәни (1754–1834), Ибраһим бине Хуҗаш (?–1823), Ярулла бине Бикмөхәммәт бине Котлыпулат (?–1670),



К.Насыйри. Календарь 1878 нче елга. Казан, 1877.

Мөхәммәт Чәләби (?–1532), Таһир бине Собханколның (?–1867) тәрҗемәи хәлләре һәм эшчәнлекләре бәян ителә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1879 нчы елга. Тукызынчы ел (кәбисә елы артыннан өченче ел, 365 көн). Иҗат вә тасниф итеп тукызынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап Казан университетның табыгханәсендә басма улынмыштыр 1878 нче елда. 56 б.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Нисан ягъмуры [Апрель яңгыры]». Март аеның унтугызыннан соң яуган кар яки яңгыр нисан булганлыгы аңлатыла.

«Дәхи «Фәүзен-нәҗат»нең сүзе һәм ошбудыр». Әсәрдәге нисан яңгыры турындагы текст китерелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1880 нче елга. Унынчы ел (кәбисә елы, 366 көн). Иҗат вә тасниф итеп унынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1880 нче елда. 38 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Сәүдә хәлләре — сәүдә маллары». Башлыча, чит илгә акча алып чыгу, анда сәүдә итү тәртипләре аңлатыла.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1881 нче елга. Унберенче ел (кәбисә елы артыннан әүвәлге ел, 365 көн). Тасниф итеп унберенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1880 нче елда. 51 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Казан шәһәре». Казан шәһәрендә һәм губернасында яшәүче халыкларның саны, өяз шәһәрләренең атамалары китерелә.

«Казан шәһәре хакында риваять». Казан шәһәре төзелү турында өч риваять (урын сайлау, кальга нигезенә эт салу, җирне еланнардан арындыру), ханнарның исемнәре китерелә, Казан шәһәренең рус гаскәрләре тарафыннан яулап алынуы бәян ителә.

«Казан бәете»ндә мәзкүр Үлмәс вә Әбелгалак хакында риваятьләр». Нор-

лат авылында яшәүче Үлмәс исемле кешенең Габделкасыйм һәм Габделхаликъ (Әбелгалак) исемле улларының Казанны рус яуларыннан саклап сугышулары, Арча кыры, Сукно, Җиләк, Бишбалта бистәләре тарихы, Казандагы янгынннар турында бәян ителә.

«Тәфтиш вә игътизар [Тикшерү һәм аңлату]». Казанда төрле елларда нәшер ителгән Коръәндәге кайбер хаталар, пәйгамбәрләр арасындагы елларның саны китерелә; «Мөтәвәфа [вафат] адәмнәр хакында». Ислам динендәге дүрт мәзһәбкә нигез салучы Имам Әгъзам (Ногман бине Сабит), Имам Мәлик, Имам Шәфигъ, Имам Әхмәд турында бәян ителә.

«Бу заман җәгърәфиясенә тәкъсимнәт бинаән [бүленешенә нигезләнеп]». Европада, Азиядә, Африкада, Америкада, Австралиядә яшәүчеләрнең саны китерелә.

«Ихтиляф ләгать вә интишар өмәм [Төрле телләр һәм таралган өммәтләр]». Җир йөзендә төрле халыклар һәм аларның телләре таралу сәбәпләре бәян ителә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1882 нче елга. Уникенче ел (елкы елы, кәбисә елы артыннан икенче ел, 365 көн). Тасниф итеп уникенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1881 нче елда. 51 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Казанның кадимге ихатасы хакында риваятьләр». Казанның борынгы кальгасының имән бүрәнәләрдән ясалганлыгы, унике капкасы булганлыгы һәм диварының иңе руслар тарафыннан яулап алынганнан соң төзелгән таш кальганыкыннан киңрәк булуы әйтелә.

«Әммә тавы хакында риваятьләр». Рус яулап алуларыннан соң татарлар Казаннан куылгач, Әммә тавында Әхмәт исемле кеше яшәгәнлеге, тора-бара анда авыл хасыйл булганлыгы сөйләнелә.

«Хан мәсҗеде хакында риваятьләр». Сүз хәзерге Казан Кремлендәге Сөембикә манарасы һәм аның төзелү тарихы турында бара.

«Кабан күле хакында риваятьләр». Казанны руслар яулап алганнан соң, аннан куылган татарларның хәзерге Кабан күле буена урнашулары, анда Касыйм шәех исемле изге затның чишмә табуы, төрле хасталыклардан котылу өчен аның рухына дога кылдырулары, нәселеннән булганнарга сәдака бирүләре бәян ителә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1883 нче елга. Унөченче ел (куй елы, кәбисә елы артыннан өченченче ел, 365 көн). Тасниф итеп унөченче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы әш-Шырдани. Бу китап Казанда Перовның ташбасмаханәсендә табыг кылынды [елы күрсәтелмәгән]. 40+8 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Телемездә истигъмаль кылына [файдалана] торган бәгъзе фарсы сүзләре». Татар телендә кулланылышта булган йөз кырыклап фарсы сүзенең аңлатмасы бирелә.

«Алып адәмнәр». Болгар илендә яшәгән алып кешеләр турында сөйләнелә.

«Тәзкирә». Казандагы кайбер татар байлары турында этрафлы мәгълүмат урнаштырыла.

«Көсуф вә хөсуф [Кояш һәм ай тотылу] хакында Чәгъминидән бераз гыйбарәт». Харәземле борынгы математик, астроном һәм табип әл-Чәгъмининең астрономиягә багышлап гарәп телендә язган хезмәтеннән өзек оригиналда китерелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1884 нче елга. Ундүртенче ел (пичин елы, кәбисә елы, 366 көн). Тасниф итеп ундүртенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы әш-Шырдани. Бу китап басма улынмыштыр Казан университетының табыгханәсендә 1883 нче елда. 40 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Елларның казакъча исемнәре». 1885 елдан 1893 елга кадәр елларның тавык, эт, дуңгыз, сычкан, сыер, барс, куян, ләү, елан дип аталачагы һәм аларның сыйфатлары белдерелә.

«Мөгыйн әд-дин [Дин ярдәмчесе]». Башлангыч сыйныфта укучы шәкертләргә укытылырга тиешле китаплар тәкъдим ителә.

«Кыйбла». Карта һәм компас ярдәмендә кыйбланы табу ысулы өйрәтелә.

«Ут хәүфеннән сакланмакның тәртибе». Авылларда ут казасыннан саклану өчен 1876 елда басылган законнар җыентыгыннан кайбер маддәләр китерелә.

«Карьяләрдә йорт вә гыймарәт төземәк». Авылларда йорт һәм башка каралтылар төзү турында алда әйтелгән законнар җыентыгыннан кайбер маддәләр китерелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1885 нче елга. Унбишенче ел (тавык елы, кәбисә елы артыннан беренче ел, 365 көн). Тасниф итеп унбишенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1884 нче елда. 50 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Тел вә лөгать». Чит телләрне өйрәнү өчен иң элек үзеңнең туган телеңнең кагыйдәләрен яхшы белергә кирәклеге турында сөйләнелә, гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрнең татар телендә ничек әйтелергә һәм язылырга тиешлеге күрсәтелә.

«Зоһуре мәмалик Төркестан [Төркестан дәүләтләренең барлыкка килүе]». Мәгълүм җир йөзен су басудан (туфаннан) соң Урта Азиядә барлыкка килгән татар һәм магул кабиләләре, тора-бара идарәнең соңгысына күчүе, әмма ханлыкның татар исеме белән аталып калуы хакында мәгълүмат китерелә.

«Чәй — каһвә — себерке». Ривайтьләргә нигезләнеп, Болгарга килгән сәхабәләрнең ханның авыру кызын каен себеркесе белән терелтүләре.

Хуҗа Әхмәт Ясәви әйткәнчә чәй, шәех Гомәр әйткәнчә каһвә эчеп дәвалану хакында сөйләнелә.

«Әт-тәфтиш вәт-хаким [Тикшерү һәм хөкем итүче]». Пәйгамбәр сәхабәләренең Болгарга килүләре, Айдар ханның кызы Туйбикәне дәвалаулары, ислам диненең ни рәвешле таралуы хакында бәян ителә.

«Әхвале бәдән инсан вә хифыз сыйххәт [Кешенең тәне хәлләре һәм сәламәтлек саклау]». Һава торышларының кешегә тәэсире, ашау-эчүне тиешле күләмдә генә кабул итү, суның чисталыгы һәм файдасы мәсьәләсе карала.

«Әдвияи мөфридә [Файдалы дәвалар]». Даруханәләрдән кирәкле дарулларны алуны җиңеләйтү максатында

аларның гарәпчә, русча, латинча язылган исемлеге бирелә.

«Китап сәүдәсе». Казанда китап сәүдәсе белән шөгыльләнүче Шәмсетдин Хөсәен угылы тарафыннан бастырылган һәм шулай ук үзендә сатылачак китапларның исемлеге китерелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1888 нче елга. Уналтынчы ел (сычкан елы, кәбисә елы, 366 көн). Тасниф итеп уналтынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1887 нче елда. 52 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Йорт өчен йимеш киптермәк вә йимешләрдән мөрәбба [кайнатма] хәзерләмәк». Алма һәм миләш җимешләрен киптерү һәм алардан кайнатма ясау ысуллары өйрәтелә.

«Өч йөз йитмешләп дәва үләннәренең исемнәре русча, латинча, мөселманча». Дару үләннәренең русча, латинча, татарча һәм гарәпчә исемлеге бирелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1889 нчы елга. Унҗиденче ел (сыгыр елы, кәбисә елы артыннан әүвәлге ел, 365 көн). Унҗиденче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1888 нче елда. 45 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Аракы дигән эчемлек адәми зат өчен сарыф бер агудыр». Аракының кешегә зарары, аракы китереп чыгара торган авырулар турында әйтелә.

«Оренбургның Мәхкәмәи исламия нәвахисиндә [өлкәләрендә] булгучы муллалар өчен Нәзарәте гыйльмия низамнарын вазгы кылу [гыйлем канунарын билгеләү]». Муллалык, ахун вазифаларын башкарганда рус телендә сөйләшә һәм яза белү өчен куелган таләпләр турында әйтелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1890 нчы елга. Унсигезенче ел (барс елы, кәбисә елы артыннан икенче ел, 365 көн). Унсигезенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1890 нчы елда. 40 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Томау зәхмәтенә Дубсун дигән табибның дәвасы». Ярты стакан кайнар суга кафур уып салып, шуны борын белән суларга киңәш ителә.

«Ачкылыкны дәфегъ кылу». Кешенең үзенә ике кулының шәһадәт бармагы белән колагын каплап, икенче кеше аңа су эчерергә тиешлеге әйтелә.

«Күзгә чүп керсә». Чүп кермәгән күзне уарга һәм икенче күздәге чүп әкрен-әкрен борын төбенә таба килгәч, аны алырга.

«Авыздан әшәке исене бетерү». Теш черү сәбәпле, авыздан яман ис килгән очракта бор кислотасы белән чайкарга киңәш ителә.

«Теш авыртканга». Бака яфрагын аракыга салып төнәтергә һәм шуны мамык белән авырткан тешкә куярга.

«Әхвале шәраб әд-дөхан». Шәраб эчүнең һәм тәмәке тартуның зарары турында бәян ителә.

«Бала тәрбия кылгучы хатыннарга нәсыйхәт». Баланы тәрбияләү, имчәктән аеру, имчәк баланы тирбәтү, бала-

ны пөхтә тоту мәсьәләләре буенча киңәшләр бирелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1891 нче елга. Унтукызынчы ел (барс елы, кәбисә елы артыннан өченче ел, 365 көн). Унтукызынчы мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1890 нчы елда. 35 б.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Ибтида мәмалик Госмания [Госманлы мәмләкәтенең башлануы]». Госман бине Иртогрыл тарафыннан нигезләнгән Госманлы мәмләкәтенең утызынчы солтанына кадәрге тарихы тасвирлана.

«Тәрбия». Җан-тәнне, баланы тәрбияләүнең төрле чаралары күрсәтелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1892 нче елга. Егерменче ел (ләү елы, кәбисә елы, 366 көн). Егерменче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1891 нче елда. 48 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Гимназиянең әүвәлге дүрт дәрәҗәсендә укыла торган фәннәр ошбулардыр». Әүвәлге дәрәҗәдә Закон божий, пәйгамбәрләр тарихы, рус теле, латин теле, математика, география, язу, геометрия; икенче дәрәҗәдә Закон божий, пәйгамбәрләр тарихы, рус теле, латин теле, математика, география, француз һәм немец телләре, язу, геометрия; өченче дәрәҗәдә Закон божий, рус, латин, грек, немец телләре, алгебра, рус тарихы, география; дүртенче дәрәҗәдә Закон божий, рус, латин, юнан, француз, немец телләре, геометрия, борынгы заман тарихы, география фәннәре укытылуы бәян ителә.

«Каванине хокукыя әл-хидмәт әл-җәвамиг [Мәчет хезмәтенә керү өчен хокук кануннары]». Муллалык вазифасына ия булу өчен 1890 елның 1 октябрендә патша тарафыннан чыгарылган канунның ундүрт пункты китерелә.

«Китаб әт-тәрбия». Йөз дә унөч тәрбия чарасына иллюстрация буларак төрле вакыйгаларны тасвирлаган риваятьләр урнаштырыла.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1893 нче елга. Егерме беренче ел (елан елы, кәбисәдән соң ел, 365 көн). Егерме беренче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1892 нче елда. 47 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Янә хат башларында мөстәгъмәл булгучы [кулланыла торган] фикърәләр [өзекләр]». Дуска, гыйлем иясенә яза торган хатларның башлам өлешенә үрнәкләр китерелә.

«Макарья ярминкәсе (Асылда Казан ярминкәсенең каим мәкамедер) [вакытлыча үтәүчеседер]». Мәкәрҗә ярминкәсенең башлангычы итеп Казан ярминкәсе күрсәтелә һәм аның алга таба Русиянең төрле патшалары идарәсе вакытындагы тарихы тасвирлана. «Макарья ярминкәсе өчен Император әгъзамның әмере белән вазгы кылынмыш кавагадәте низамия (Игълан кылынды)». Ярминкәдә сәүдә итү өчен кибетләр алу, теге яки бу сәбәпләр белән килми калган очракларда

алардан файдалану-файдаланмау тәртипләре бәян ителә. «Макарьяда сәүдә кылгучылар өчен лязем нәрсәләр». Ярминкәдә сату итү урыннары, сатылачак товарларны билгеле бер тәртип белән урнаштыру, янгынга каршы хәстәрлек чаралары күрү, тиз бозыла торган әйберләрне саклау, каравылчылар яллау, электр утының төрле урыннарда бирелеше, ризык әзерләү, тәмәке тарту, мич ягу тәртипләре аңлатыла; «Низамәт лязимә» [Тиешле кагыйдә]. Түбән Новгород башлыгы генерал-майор Баранов имзалаган кагыйдәләрдән өземтәләр китерелә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1894 нче елга. Егерме икенче ел (елкы елы, кәбисәдән соң ел, 365 көн). Егерме икенче мәртәбә бастырадыр Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Ошбу календарь Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1893 нче елда. 37 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Мәлязи мәдар әл-вөҗүд» [Гәүдә ләззәтләренең төп нигезе]. Кеше өчен дөньядагы дүрт ләззәт күрсәтелә: ашау, симаг, җимаг, мәлбәс; «Сәфәр». Үзенең Оренбург шәһәренә, Сәгыйть бистәсенә сәфәре бәян ителә.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1896 нчы елга. Егерме бишенче ел (кәбисә елы, 365 көн). Өч елны тарых кылынып егерме биш елдан бирле чыкадыр. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының таснифыдыр. Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1895 нче елда. 22 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Земельный банклар». Россиядә мондый банклар булган шәһәрләрнең исемнәре күрсәтелә, җирне залогка салучыга акча бирү тәртибе аңлатыла.

«Шәригать кашында васыять». Бу төр васыятьнең аңлатмасы китерелә.

«Русия законынча васыять». Законның шәрехләмәсе китерелә.

«Ят баланы угыллыкка беркетү һәм үзеннән никахсыз туган баланы законный итеп беркетү тугрысында 1891 нче ел 16 нчы мартта чыккан закон». Бу законның аңлатмасы бирелә.

«Кыйбла танымак бәяны». Картада күрсәтелгән сызыклар нигезендә кыйбланы табарга өйрәтелә.

«Даре казәдин Мөхәммәдия Оренбургыядан мәхәллә имамнарына фәрман 1894 нче елда 31 нче мартта номер 1556 нчы». Мәхәллә имамнарына чираттагы ялны алу тәртипләре бәян ителә.

«Һаваны тану тәжрибәләре». Кояшның чыгуы һәм баюына, яңа ай, йолдызлар торышына, хайваннар һәм кошларның үз-үзләрен тотышына, ел фасыллары һәм айларына карап һава торышын фаразлау китерелә.

«Нәсыйхәтләр». Дөрес итеп йоклау, бакчадагы корткычлар белән көрәшү ысуллары, гомерне озайту, балдан, колмактан файдалану, әйбердәге тапларны, керләрне бетерү һ.б. турында көнкүреш киңәшләре бирелә.

«Игъланнар». Казанда Әхмәтҗан Сәйдәшевнең уллары белән сәүдә ширкәтенә Бакый Субаевның кушылуы һәм ширкәтнең исеме үзгәрүнең расланыу турында.

Р.Ф.Исламов.

КАЛЕНДА́РЬ 1897 нче елга. 26 нчы ел (кәбисә елы артыннан әүвәл ел, 365 көн). Өч елны тарых кылынып екерме алты елдан бирле чыкадыр. Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылының таснифыдыр. Казан университе-

тының табыгханәсендә басма улын-мыштыр 1896 нчы елда. 35 бит.

Биредәге рубрикаларның 1871 елгы календарьдан аермасы түбәндәгедән гыйбарәт:

«Даирәи Һиндийә» [Һинд түгәрәге]. Җирне тигезләп, түгәрәк сызып, аның уртасына утыртылган казыкның шәүләсе ярдәмендә вакытны билгелү бәян ителә.

«Сөммәт кыйбла». Кешегә үзе яшәгән урында «Даирәи Һиндийә» яки башка махсус приборлар ярдәмендә кыйбланы дөрес билгеләргә өйрәтелә.

«Харитаи сәмут кыйбла». Карта ярдәмендә, сызыклар сызып, кыйбланы табарга өйрәтелә.

Р.Ф.Исламов.

КАМА́ЛОВ Абрик Закир улы (12.01.1943, Башкортстан АССРның Кыйгы районы Түбән Кыйгы авылы), механика өлкәсе галиме, физика-математика фәннәре кандидаты (1971). РФнең Югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2003). Фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2013).

Казан университетының механика-математика факультетын тәмамлаганнан соң (1965), СССР ФАнең Казан филиалы Физика-техника институтында эшли: лаборант, стажёр-тикшерүче, кече фәнни хезмәткәр (1964–1973). 1975 елдан Казан архитектура-төзелеш университетында: өлкән укытучы (1973–1974), доцент (1975–1977), теоретик механика кафедрасы мөдире (1977–1978), профессор (1997–2013). Бер үк вакытта «Фән һәм тел» журналы редакциясе мөхәррире (1997–2010).

Хезмәтләре конструкцияләрдәге юка стеналы элементларның ныклыгы, тотрыклылыгы һәм тирбәнешләре



А.З.Камалов

мәсьәләләренә карый. Югары техник уку йортларында татарча укыту өчен дәреслекләр яза, уку-укыту куллланмалары төзи, татар телендә теоретик механика буенча тулы укыту-методик әдәбият комплексын эшли. «Югары уку йортларында татар телендә укытуның теоретик һәм гамәли нигезләре (Казан архитектура-төзелеш университеты мисалында)» коллектив хезмәтендә (автордашлары — татар телендә укыту методик кабинеты мөдире Р.Ә.*Шакиржанов*, профессор Н.К.*Туктамышев*) татар телендә югары белем бирүне концептуаль һәм фәнни-методик яктан тәэмин итү, әлеге университетта татар телендә укытуны тормышка ашыру, уку-укыту–методик комплексларны төзү, татар телендә укытуны мәгълүмати һәм терминологик яктан тәэмин итү буенча күп еллар дәвамында алып барган эш нәтиҗәләре бирелә.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк «Югары уку йортларында татар телендә укытуның теоретик һәм гамәли нигезләре (Казан архитектура-төзелеш университеты мисалында)» коллектив хезмәте өчен бирелә.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Теоретик механика. Казан, 1996; Свободные и параметрические колебания цилиндрической оболочки бесконечной длины в акустической среде // Авиационная техника. 1966. № 4 (автордаш); Обтекание упругой оболочки вращения // Исследования по теории пластин и оболочек. Казань, 1973. Вып. 10; Теоретические и практические основы обучения в

высших учебных заведениях на татарском языке. Казань, 2013 (автордаш).

Әд.: Акмалов Н. Төзү — татар һөнәре! // Мәгърифәт. 2006. 29 апрель; Казанский университет (1804–2004): Библиографический словарь. Казань, 2004. Т.2.

Ф.Г.Камальтдинова.

КАРАДУГА́Н БАЛАЛА́Р БАКЧАСЫ́, ТР Балтач муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү оешмасы. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1998). Балтач районы Карадуган авылында урнашкан. 1979 елда ачыла.

Эшчәнлегендә рухи-әхлакый тәрбия нигезенең төп өлешләреннән булган халык бәйрәмнәрен, йолаларын, гореф-гадәтләрен балаларга җиткерү һәм аларда мәдәнияткә, халык традицияләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү аша туган телгә (татар теленә), үз халкына карата мәхәббәт, милли үзаң, әхлакый кешелек сыйфатлары формалаштыруга юнәлеш тота. Коллектив әгъзалары Татарстан Республикасында 2010–2015 елларга «Киләчәк» мәгариф үсеше стратегиясе кысаларында ике дәүләт теленә өйрәтү буенча уку-укыту–методик комплект әзерләү буенча иҗади төркемгә керә. 2016 елдан татар телендә белем һәм тәрбия бирү буенча балалар бакчасы республикакүләм тәжрибә мәйданчыгы итеп билгеләнә.

«Педагогический вестник» газетасы тарафыннан уздырылган «Ел балалар бакчасы» бәйгесе лауреаты (1996). Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы «Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы тарафыннан республика күләмендә уздырылган «Шәҗәрә — безнең тамырлар» (2015), «Бишек туе» (2016) бәйгеләрендә конгрессның, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамоталарына, шулай ук «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» исеменә (2015, 2023) лаек була.

Коллективның казанышлары балалар бакчасының беренче мөдире, аның 33 ел дәвамындагы җитәкчесе, ТРның атказанган укытучысы, Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы «Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының Балтач бүлеге җитәкчесе З.Ф.Камалова эшчәнлеге белән бәйле. Аның тарафыннан эшләнеп, ике кисәктән торган «Балалар бакчасында тәрбияләү һәм укыту программасы» нәшер ителә, шулай ук «Балалар бакчасы һәм гаилә өчен ана теле программасы» Әстерхан, Пермь, Чаллы шәһәрләрендә кабат бастырыла. Әлеге программа нигезендә З.Ф.Камалова «Балалар бакчасы өчен хрестоматия» төзи, ул «Гөлбакча» исеме белән 1990 елда дөнья күрә. Коллектив мөдир җитәкчелегендә эти-әниләр һәм тәрбиячеләр өчен «Юлда йөрсәң бул өлгер, юл кагыйдәләрен нык бел» (1982), «Горурланам синең белән, әй мөкатдәс, моңлы тел!» (1992), «Адымнар нык, юллар имин булсын» (1997), «Үткәннәргә борылып карый-карый, алга таба киләчәккә барам» (1998), «Матурлык иленә юл» (2001), «Табигать дуслары булыйк» (2007), «Балалар бакчасында түгәрәкләр» (2016) һәм башка методик кулланма материаллар эшләп бастыра.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк милли тәрбия бирү һәм туган телне өйрәтү өлкәсендәге казанышлары өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

«КАСЫЙМИЯ́», Казан мәдрәсәсе; мөселман дини уку йорты. 1770 елда ачыла, башта Апанай мәчетендә эшли, аннан соң агач бинага күчә. 1877 елдан Кабан күле буенда Казан архитекторы П.И.Романов проекты буен-

ча сәүдәгәрләр Әхмәтҗан Рәхмәтуллин һәм Ибраһим Юнысов акчасына төзетелгән махсус бинада урнаша. 20 йөз башыннан Апанай мәчете имамы (1899–1930) һәм мәдрәсә мөдәррисе (1899–1918) Мөхәммәткасыйм Салихов (1871–1954) исеме белән «Касыймия» дип атала. Шулай ук «Апанай мәдрәсәсе», «Күл буе мәдрәсәсе» исемнәре белән дә мәгълүм.

Каюм Насыйри, авыл мәктәбендә белем алганнан соң, укуын дәвам итү өчен, 1841 елда атасы Габденнасыйр хәзрәт киңәше белән Казанга, «Касыймия» мәдрәсәсенә (ул чакта — Күл буе мәдрәсәсе) юл тота. Бу вакытта анда авылдашы һәм гаиләләренең дусты, дини тәгълиматны яңартучы Габденнасыйр Курсави тарафдары Әхмәт бине Сәгыйть *әш-Шырдани* имамлык һәм мөгаллимлек итә. Аның җитәкчелегендә К.Насыйри төрек, гарәп, фарсы телләрен, мөселман фәлсәфәсе һәм хокукы нигезләрен үзләштерә.

Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә 1830–1875 елларда мөгаллимлек иткән өч имамны аерым билгеләп үтә. Алар — аталы-уллы Исхак (1831 елда имам булып сайлана) һәм Сәлахетдин Сәгыйтовлар, Мөхәммәткәрим Мөхәммәтрәхимов. Соңгысы 1836–1861 елларда имам һәм мөгаллим вазифаларын башкара, мәдрәсәдә 1841–1855 елларда укыган К.Насыйриның остазларыннан берсе була. Ш.Мәрҗани хезмәтендә (ул мелла Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим бине Гаид әт-Тәкәнеши дип күрсәтелә) аның эшчәнлегенә кагылышлы «Шәкертләре күп була. Рәсми дәресләрендә намуслылык һәм дөрес юнәлеш табарга мөмкин булса да, хакыйкатьне эзләү, җентекле тикшерү алымнары, башкалар буенча җитешсезлеге күренә» дигән сүзләр бар. Сәлахетдин Сәгыйтов (аңарда Галимҗан Баруди укыган) эшчәнлеге дә шулайрак бәяләнә.

19 йөз уртасында әлеге мәдрәсә иң абруйлы уку йортларының берсе саналган. 1870 елларда анда 300 ләп шәкерт белем алган.

Әд.: Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVIII гасыр ахыры — XX гасыр башы). Казан, 1995. № 33; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. Казань, 1993. № 650.

И.Х.Хәлиуллин.

КАТА́НОВ Николай Фёдорович (06.05.1862, Изюм (Узюм) даласы, хәзерге Хакас Республикасының Аскиз районы – 10.03.1922, Казан), төрки телләр галиме, этнограф, филология докторы (1903), чагыштырма тел белеме докторы (1907), хакыйкый статский советник (1915). Рус географияһәм Рус археология җәмгыятьләре (икесе дә — 1894 елдан), Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (1896–1998 елларда — секретарь; 1898–1914 елларда, 1919 елдан — рәис) хакыйкый әгъзасы.

Красноярск гимназиясен (1884), Петербург университетының шәрекъ факультетын (1888) тәмамлый. 1889–1892 елларда Рус географияҗәмгыятенең һәм Петербург Фәннәр академиясенең Себер, Монголия, Җоңгария, Кытай, Төркестан экспедицияләрендә катнаша; җирле төрки халыкларның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, телен, фольклорын өйрәнү белән шөгыльләнә. 1893 елдан Казан университетының төрек-татар шивәләре кафедрасында экстраординар профессор. 1896–1898 елларда Уфа губернасының көнбатыш өязләрендә башкорт теле диалектларын өйрәнә; «Башкорт теле әлифбасы»н («Азбу-

ка башкирского языка») төзи (басылмаган). Соңрак — Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетында шәрекъ, шул исәптән татар басмалары цензоры һәм әҗнәбиләр өчен дәреслекләр мөхәррире. 1907 елдан Тәрҗемә комиссиясе рәисе. 1911 елдан Казан руханилар академиясендә Идел буендагы христианлык тарихыннан лекцияләр укый, татар теле укыта. «Кыскача татарча-русча сүзлек» («Краткий татарско-русский словарь», 1912), академия тыңлаучылары өчен татар телендә хрестоматия бастырып чыгара (1913). Бер үк вакытта этнография музее белән җитәкчелек итә, «Православный собеседник» журналының «Инородческое обозрение» кушымтасы мөхәррире була. 1917 елдан соң — кабат Казан университетында (1921 елдан — профессор). Лекцияләрендә төрки телләрнең таралу географиясе һәм классификациясе, төрки язу тарихы буенча мәгълүматлар бирә. Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография, Югары халык мәгарифе институтларында да укыта.

Төрки тел белеме һәм этнография буенча хезмәтләре бар. «Урянхай телен өйрәнү тәжрибәсе» («Опыт исследования урянхайского языка», т. 1–2, 1903) хезмәтендә урянхай (тыва) теленең грамматик төзелеше башка төрки телләр грамматикасы белән чагыштырып карала; анда халык авыз иҗаты үрнәкләре дә, сүзлек тә бирелгән. Шулай ук Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы һәм Казан тарихлары белән кызыксына: археологик казу эшләре вакытында табылган акчаларны, болгар эпиграфик истәлекләрен, матди мәдәният ядкәрләрен өйрәнә.

Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте нәшер иткән «*Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*»ндә һәм «*Деятель*» журналында татар зыялыларының, галимнәренең, шул исәптән Каюм Насыйриның эшчәнлегенә күзәтү алып бара, аларның әсәрләренә бәяләмәләр бастыра. 1896 елда «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»нең 13 нче томында К.Насыйриның «Казан татарлары халык әдәбияты үрнәкләре» мәкаләсе дөнья күрә. Катанов аңа кереш сүзендә: «Хәзер Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә хакыйкый әгъза Габделкаюм Насыйров тарафыннан шушыларны үз эченә алган мәкалә тәкъдим ителә: 28 табышмак, 243 мәкаль һәм 145 җыр. Насыйров әфәнде Казан татарлары халык иҗаты ядкәрләреннән үзеннән элгәре җыючыларга караганда беренче мәртәбә артыграк шундый күп мәкаль һәм җырлар тәкъдим итте. Насыйров әфәнде тәкъдим иткән материаллар белән аның үзе гомер буе алар арасында яшәгән халкының көнкүрешен һәм телен белүен тулысы белән дәлилли», — дип яза.



Н.Ф.Катанов

«*Деятель*» журналының «Шәрекъ библиографиясе» бүлегендә Катанов К.Насыйри хезмәтләрен (алар Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә) тасвирлауга аерым игътибар юнәлтә. Журналның 1897 елгы 2 нче санында галимнең «Кавагыйде лисане гарәб» («Гарәп теле грамматикасы») хезмәтен анализлап, аның отышлы якларын һәм шул ук вакытта кимчелекләрен дә күрсәтә. Дәреслек катгый система кысаларында бирелеп, һәр кагыйдә гарәп теленнән мисаллар белән ныгытылуга карамастан, сүзләр-

нең гарәп телендәге а, и, у сузык авазлары хәрефләрен һәм башкаларны аңлаткан билгеләр (хәрәкәләр) куелмау, өстәвенә китапның исеменнән гайре аның барлык эчтәлеге фәкать гарәп телендә генә булуы, борынгы гарәп грамматика терминнарының мул кулланылуы, аларның да шул ук гарәп телендә генә аңлатылуы сәбәпле, Катанов әлеге дәреслекне грамматика укытучысыннан башка гына укучыларның бер ел эчендә үзләштерә алмавы, бу очракта аның авторының аңарчы ук гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән балаларны һәм аларга сабак бирергә сәләтле мөгаллимне күздә тотуы хакында нәтиҗә ясый, татар галимнәренең гарәп грамматикасын үз телләрендә аңлатмавын «затлы гарәп телен тупас мужик аңлатмалары белән бозарга» теләмәүләрендә күрә.

Журналның 1898 елгы 5 нче санында Катанов К.Насыйриның берьюлы дөнья күргән «Кабуснамә тәрҗемәсе»нең 2 нче басмасына һәм «Әхлак рисәләсе»нең 4 нче басмасына күзәтү ясый, аларның киң даирә өчен аңлаешлы, камил татар телендә язылуын ассызыклый.

«Деятель»нең 1898 елгы 6–7 нче кушма санында К.Насыйриның шул ук елда чыккан «Китаб әт-тәрбия» («Тәрбия китабы») хезмәтенең 2 нче басмасы анализлана. Н.Катанов авторның балада чын кешелек сыйфатлары тәрбияләү асылын яктыртуын, гамәли дәлилләр сыйфатында башлыча Гарәбстанның һәм Иранның бөек шәхесләре тормышыннан китерелгән мисаллар рәвешендә тәкъдим ителгән кечерәк 86 хикәятләр урнаштыруын югары бәяли, 24 битлек брошюрадагы кайбер фикерләрнең Инҗилдәге якын кешегә карата мәхәббәт турындагы тәгълимат белән охшашлыгын искәрә.

Шул ук елдагы 8–9 нчы куш санда К.Насыйриның яңарак кына чыккан «Җәваһир әл-хикәят» («Хикәяләрнең җәүһәре») әсәренең 5 нче басмасын күздән кичереп, аның 1505 елда вафат булган гарәп илаһият галиме һәм тарихчысы шәех Җәләлетдин Габдрахман ибн Әбубәкер әс-Сойутиның «Әнисел-җәлис» китабының татар теленә тәрҗемәсен һәм тәкъва мөселманнар тормышының төрле эпизодлары бәян ителгән 50 дән артык хикәятне үз эченә алуына басым ясый.

Журналның 1901 елгы 5 нче санында Катанов галимнең «Санаигы голфания» («Гальваника эшләре») хезмәтенә югары бәя бирә, авторның мөселманнар тарафыннан Европа фәне казанышларын сүлпән үзләштерүенә борчылуын, хәзер гальваникага багышланган китабын нәшер итеп, үзенең диндәшләренә файда китерергә омтылуын белдерә.

Казандагы бер урамга һәм Хакас университетына Н.Катанов исеме бирелә.

Хезм.: Вступительное слово / Насыров А.К. Образцы народной литературы казанских татар // Известия Общества археологии, истории и этнографии. Казань, 1896. Т.XIII, вып.5; Книга «Каваиди-лисани-араб» («Правила арабского языка») // Деятель. 1897. № 2; «Ахляк рисалесы» («О нравственности») // Деятель. 1898. № 5; «Джауагируль-хикаять уа ль-асъиле уа лятаифур-риуаять уа ль-амсиле» («Драгоценности рассказов и вопросы остроумия предания и притчи») // Деятель. 1898. № 8–9; «Кабус-наме терджемесе» (Перевод книги «Кабус-наме» // Деятель. 1898. № 5; «Тербия китабе» («Книга воспитания») // Деятель. 1898. № 6–7; Материалы к изучению Казанско-татарского наречия: В 2 ч. Казань, 1899; «Санаи гальфание» («Работы гальванические») // Деятель. 1901. № 5; Наречия урянхайцев, абаканских татар и карагасов // Радлов В.В. Образцы народ-

ной литературы тюркских племён. СПб., 1907. Ч. 9.

Әд.: Валеев Р.М. Классик отечественного востоковедения // Научный Татарстан. 2002. № 2; Иванов С.Н. Николай Фёдорович Катанов: Очерк жизни и деятельности. М., 1973; Катановские чтения: Доклады, прочитанные в Казанском университете, посвящённые 135-летию со дня рождения Н.Ф.Катанова. Казань, 1998.

И.Х.Хәлиуллин.

КАЮ́М КОЕСЫ́, Насыйриларның нәсел коесы. Татарстанның Яшел Үзән районы *Кече Шырдан* авылында урнашкан, мәгърифәтче галим Каюм Насыйри тарафыннан 19 йөзнең 2 нче яртысында казытылган кое.

Элек-электән кое казу өчен көн белән төн тигезләшкән көннәрне сайлаганнар. Ул вакытта сулар түбәнгә китә торган була. Кое казу – саваплы гамәл. Кое казучы кешеләргә файда китерә, димәк, ул изгелек эшли. К.Насыйри үзенең ата-бабалары турындагы истәлекләрендә: «Янә Габдерәзак бабаның ишек алдында коесы бар икән. Габдерәзак коесы урыны, дип хәзер дә әйтәләр», — дип язган. Ислам динендә җәрия сәдакасы дигән төшенчә бар: ул «бетмәс-төкәнмәс», «гел килеп тора» дигәнне аңлата. Кое казыган кешегә дә әҗер-савабы кыямәт көненә кадәр килеп торачак. Хәдисләрнең берсендә «иң хәерле сәдака ул – су эчертү» диелгән. Кое казыйсыңмы, су кертәсеңме, савыттан эчертәсеңме – мөһим түгел. Атасы Габденнасыйр, анасы Фатыйма тәрбиясендә шушы саваплы гамәлләрне күреп-белеп үскән, дини-дөньяви белем алган К.Насыйри үз йорты янында кое казыта.

Коеның чокыры һәм өстәге өлеше агач бура белән уратып алынган. Ул чыгырлы кое рәвешендә корылган, ягъни коеның өске бурасында чиләк белән су чыгару өчен чылбырны урата торган йомры агач борыс урнаштырылган. Аның суы белән озак еллар дәвамында Насыйрилар гаиләсе һәм тирә-як күршеләр файдаланганнар.

Әлеге объект — Кече Шырдан авылында Каюм исемен саклаучы кадерле ядкәр. Авыл халкы, гомумән, элек-электән чишмә-коеларга игътибарлы була, алар Каюм бабалары коесын чистартып, төзекләндереп һәм тәрбияләп тора. 2018 елда А.Н.*Гобәйдуллина* җитәкләгән «Акведук» ҖЧҖ һәм авыл җирлеге тарафыннан Каюм коесы төзекләндерелә. Заманча технологияләр кулланып, аны элеккеге хәленә кайтаралар. Җир өстенә чыккан өлешен — «кое авызын» элеккесенә охшатып буралап куялар. Кое — түбә



Каюм коесы.

астында. Объект урнашкан мәйданчык өч яктан койма белән уратып алынган. Төп юлдан коега керү сукмагына таш җәелгән. Ике телдә «Кое – Каюм Насыйри чорының шаһите һәм туган йорты урнашкан урынның күрсәткече. Каюм Насыйри, паспорты буенча, гомеренең ахырына кадәр Кече Шырдан авылы крестьяны булып исәпләнгән», – дип язылган күрсәтмә такта куелган. Биредә шулай ук истәлек тактасы урнаштырыла (2018), анда татар һәм рус телләрендә: «Монда бөек татар мәгърифәтчесе һәм галим Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйриның 1825 елда туган һәм 1902 елга

кадәр төрле елларда яшәгән йорт урыны» дигән сүзләр язылган.

Хәзер ул — туристлык объекты. К.Насыйри эзләре буенча оештырылган экскурсия шушы коедан башланып китә. Кунакларга экскурсия хезмәте күрсәтүче Г.Ю.*Минһаҗева* Каюм казыткан коедан су эчертә, алар исә бит-кулларын юалар, сусауларын басалар.

Күренекле татар шагыйрәсе Э.М.*Шәрифуллина* мәгърифәтче галимгә һәм аның исеме белән аталган коега багышланган «*Каюм коесы*» поэмасын яза. Шуннан бер-ике юл китереп үтик:

Гыйлем сөйгән Каюм бабабызның / Таза булган нәсел буыны! / Ничә гасыр яшәр гомер биреп, / Казыган ул үзенең коесын. / Якташлары, авыл кешеләре / Шифалы су белән туенсын!.. (Кара: «*Каюм коесы*» поэмасы).

Ф.Г.Камальтдинова.

«КАЮ́М КОЕСЫ́», поэма. 7 бүлектән тора. 1997 елда шагыйрә Э.М.*Шәрифуллина* тарафыннан языла.

Каюм Насыйриның туган җире — Яшел Үзән районы Югары Шырдан (хәзерге вакытта — *Кече Шырдан*) авылында урнашкан, халык телендә *Каюм коесы* дип йөртелә торган кое күздә тотыла. Әсәрдә кое образы мәгърифәтче образын ачуга хезмәт итә. Һәр бүлек К.Насыйри хезмәтләреннән китерелгән, шулай ук әдипләрнең, галимнәрнең, якташларының үзе яки эшчәнлеге белән бәйле фикерләреннән гыйбарәт эпиграфлардан башлана.

Поэмада кое — символик образ. Әлеге коедан тереклек суы гына түгел, «гыйлем суы да ага», ягъни ул гыйлем-мәгърифәт коесы буларак гәүдәләнә: «Белем алу — кое казу, энә белән казу коены». К.Насыйридан мирас булып калган гыйлем коесы аша ул яшәгән чор белән бүгенге көн арасында күпер салынуы аңлатыла. Биредә К.Насыйриның тирән белемле, күпкырлы шәхес булуы, тарихи үткәннәрне яхшы белүе турында әйтелә; туган теле — татар телен, газиз халкын, милләтен, илен зурлавына, олылавына басым ясала. Аның гомер буе «Без — татарлар, телебез — татар теле, мөстәкыйль һәм төзек, камил тел. Бүтән телдән бер дә ким түгел» дигән ышаныч белән яшәве, телне, рухи кыйммәтләрне, гореф-гадәтләрне саклау өчен күп тырышлыклар куюы, шул юнәлештә бихисап хезмәтләр язуы, халыкны агарту юлында шактый авырлыклар кичерүе турында бәян ителә. Әмма күпме генә «киссәләр дә, какса-типсәләр дә, чигенмәгән Каюм, нык торган».

Нечкә күңелле, бала җанлы кеше буларак, К.Насыйриның балалар күңелен күрүе, алар өчен бәйрәмнәр оештыруы, аларга мәгърифәт таратуы турында да хәбәр ителә.

Мәгърифәтче галим татар халкының гыйлемле, һөнәрле булуын теләгән, «милләт дәрәҗәсен, милләт данын өскә күтәргән. Татар халкы эшчән, мәгърифәтле, зур халык дип фикер үткәргән». Поэмада төп фикер — телне бетермәү, аны саклау, мәгърифәт коесын бервакытта да саектырмау, һәм ул халык мәкаленә аваздаш булган түбәндәге шигъри юлларда чагыла:

Телемне үтермәгез! / Соңыннан суын эчәрсез — / Коега төкермәгез!.. / Энә белән казылса тик, кое — / Каюм коесына тиңләшә!

Әсәр.: Шәрифуллина Э. Каюм коесы // Сөюемнән мин бер чибәр идем..: Шигырьләр, поэмалар. Казан, 2005.

Г.И.Каюмова.


«КАЮ́М НАСЫЙРИ́», 4 пәрдәле тарихи драма. Язучы Мөхәммәт *Галинең* режиссёр Хөсәен Уразиков белән автордашлыкта язылган пье-

сасы. 1945 елда күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулу уңаеннан иҗат ителә. Аны камилләштерүгә һәм сәхнәгә чыгаруга Х.Уразиков шактый күп көч куя.

Пьесада татар мәдәниятенең Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани кебек күренекле эшлеклеләре үзәккә алып сурәтләнә. Анда шулай ук алар яшәгән һәм эшләгән чорның ил тарихында, халык язмышында билгеле бер эз калдырган башка тарихи шәхесләре образлары да калку чагылыш таба. Аларның эшчәнлекләре, яшәү рәвешләре аркылы аерым бер тарихи дәвер күзаллана. Драманың сюжеты Каюм Насыйриның тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле вакыйга-күренешләргә нигезләнеп корыла. Әсәрдә Насыйри да, Мәрҗани да халыкны мәгърифәтле итү өчен җан-фәрманга тырышып йөриләр, дини фанатизмга, кадимчелек идеологиясенә каршы көрәш алып баралар.

Пьесадан аңлашылганча, «Бөтен Россия мөселманнарының рухани башлыгы мөфти хәзрәт Сәлимгәрәй морза Тәфкилев җәнабләре» Казанга килә. Бу төп вакыйга булып тора һәм алга таба сюжет шуның тирәсендәге ситуацияләргә бәйле рәвештә үстерелә. Казанның атаклы бае Ибраһим Юнысов һәм шәһәрнең башка хөрмәтле кешеләре кунакны зурлап каршы алырга әзерләнәләр. Драмада Ибраһим бай тискәре образларның берсе һәм иң зурысы итеп тасвирлана. Ул шәһәргә килгән мөхтәрәм кешеләрне, хәтта патшаны да кунак итеп, ихтирам күрсәтеп, ышанычларын яулый алырлык дәрәҗәдәге авторитет, зирәк һәм хәйләкәр кеше буларак ачыла.

Сюжет сызыгында төп каршылык капма-каршы караштагы ике лагерь — башында мәгърифәтче Каюм Насый-



МӨХӘММӘТ ГАЛИ

ХӨСӘН УРАЗИКОВ


Каюм Насыйри

Тарихи пьеса

Дүрт пәрдәдә бик күренешле
Вакыйга 1887 нче елларда, Казанда
бара.
1945 ел

Казан.
Бу дәфтәрдәге кулъязма әсәргә соңгы төзәтмә кертелгән
чорны чагылдыра.
1958 ел. Август. Хөсән Уразиков.
Казан.

БИБЛИОТЕКА 1951
Татарского государственного
Академического театра имени
Г.Камала в Казани



КАТНАШАЛАР:

Каюм Насыйри. - Хәмитов С.Ф.
2. Әсәлем - Каюм тәрбиясендәге, яшь бала. - Мишкина
3. Габделмәҗит - Каюмның бер туган абыйсы. - Яковлев
4. Шагыйрь - Каюмның земандашы, авылдан. - Гафуров
5. Камил - медреседән куылган пәкерт, учительский школа
студенты. - Зәйлев.
6. Смирнов профессор. Казан университеты каршындагы, ар-
хеология, җәмгыятенең рәисе. - Шомуков.
7. Ольга Федоровна Лебедова. Рус хатыны, фән әһлесе. - Чекмарева
8. Мостафа яшь язучы. - Хәйруллин.
9. Ибраһим бай Юнысов, Казанның атаклы бае. - Урманов Борганов
10. Рабига - Юнысовның хатыны. - Мишкова-Хомякова
11. Байбикә Каюмның квартир хуҗасы. - Нигъматуллина, Зинн
12. Шиһаб Мәрҗани, Ибраһимбай мәхәлләсендә мулла, татар
галиме. - Кудашев. Шәрәфиев.
13. Хәйри мәзин, шул мәхәлләдә. - Соловьев. Мурашев.
14. Сәлимгәрәй хәзрәтнең морза Тәфкилев мөфти. Ибраһим бай
кунагы. - Зиятдинов.
15. Губернатор - Казан губернасенда. - Гомаҗаров.
16. Хисамый, Зәйдуллин
17. Йосыф Хәсәнуллалар. мәһәр голамасы.
18. Ишан - Волков
19. Җәмәлый - татар Ушәрие. Сәфәрәлиев
20. Малай Типография эчесе. - Шәмәков
21. Казанлы Әсәлемнең бер туган апасы, Ибраһим бай әсрәне. Исламов
22. Дворник, бакчачы, Ибраһим бай эчендә.
24. Егет - бер сәүдәгәрнең кибетендә эшләүче.
Бәйләр, муллалар, наруз өйтүче пәкерләр,
студентлар, бай кызлары һәм халык.

ри торган алдынгы карашлылар лагеры белән Ибраһим бай Юнысов җитәкчелегендәге реакционерлар лагеры арасында барган тартыш кебек формалаша. Реакционерлар дөньяның кая таба барганын ачык чамалый. Болар йөзендә феодал аристократиясе көченең көннән-көн йомшара, алар урнаштырган борынгы дини тәртипләрнең акрынлап какшый баруы сизелә. Шул сәбәпле алар халыкны агарту, аның милли үзаңын үстерү, дөреслеккә күзләрен ачу өчен тырышып йөргән Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани кебекләрне күрә алмыйлар һәм ачыктан-ачык һөҗүмгә күчәләр.

Каюм Насыйриның иҗат дәвере Россиядә капитализмның көчле үсеш алуы, мәдәният һәм җәмәгатьчелек фикере өлкәсендә зур яңалык һәм үзгәрешләр белән сыйфатлана. Әсәрдә Каюм Насыйри да, Шиһабетдин Мәрҗани дә чор рухын нечкә тоемлаучы тирән белемле, ачык фикерле гыйлем ияләре, көчле рухлы, горур шәхесләр буларак гәүдәләнәләр. Алар мөфти, Ибраһим бай, шәһәр губернаторы, морзалар кебек «бөекләр» алдында «хисап тотканда» да үз карашларына тугры калалар.

Тулаем алганда, драма халыкчанлык рухы белән сугарылган. Биредә җырлы-биюле күренешләр, такмаклар, табышмаклар, бәетләр, мәкаль-әйтемнәр, тапкыр сүзләр урын алган, шул рәвешчә әдипнең халык авыз иҗатын тирәнтен өйрәнүче фольклорчы галим булуына да басым ясалган.

Пьеса буенча спектакль шул ук елны Г.Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә куела. 1968 елда әсәргә күпмедер үзгәрешләр кертелеп, кабат сәхнәгә менә. Төп рольләрдә: Каюм Насыйри — Ф.Халитов; Шиһабетдин Мәрҗани — Ф.Колбарисов, Ф.Шәрәфиев; Ибраһим Юнысов — Х.Уразиков, И.Баһманов; Сәлимгәрәй Тәфкилев — Г.Зыятдинов.

Чыг.: Гали М., Уразиков Х. Каюм Насыйри. Тарихи пьеса. Казан, 1945.

Әд.: Кашшаф Г. Тарихи шәхесләрне гәүдәләндерү юлында // Совет әдәбияты. 1945. № 11; Каюм Насыйри турында пьеса // Ватан намусы өчен. 1945. 14 март; Арсланов М. Спектакль «Каюм Насыри» на сцене Татарского академического театра им. Г. Камала // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2013. № 3–4.

Г.И.Каюмова.

«КАЮ́М НАСЫЙРИ́. 1825–1945 (ТУУЫНА́ 120 ЕЛ ТУЛУГА́ БАГЫШЛАНГА́Н ГЫЙЛЬМИ́ СЕ́ССИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫ́», фәнни докладлар җыентыгы. Галимнең тууына 120 ел тулу уңае белән Казанда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында 1945 елның 18–19 мартында һәм Мәскәүдә 26 мартта уздырылган гыйльми сессия материалларын үз эченә ала. 1948 елда татар һәм рус телләрендә җыентыклар дөнья күрә. Әдәбиятчы Ш.Г.*Рамазанов* мөхәррирлегендә татар телендә басылган җыентыкка Казан һәм Мәскәү галимнәренең гыйльми сессиядә ясалган докладлары, Каюм Насыйриның туганнары, авылдашлары, якын танышларының истәлекләре керә.

Әдәбият галиме Мөхәммәт *Гайнуллинның* «Каюм Насыйри тормышы һәм иҗат юлы», тюрколог Николай *Дмитриевның* «Каюм Насыйри — филолог», Ш.Рамазановның «Каюм Насыйри — татар әдәби теленә нигез салучы», тел галиме Вәли *Хангилдинның* «Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе», тарихчы Николай *Воробьёвның* «Каюм Насыйри — этнограф», фольклорчы Хәмит *Ярминең* «Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эш-

чәнлеге», әдәбиятчылар Җамал *Вәзиеваның* «Каюм Насыйри һәм балалар әдәбияты» һәм Мөхәммәт *Галинең* «Каюм Насыйриның кулъязма мирасы» мәкаләләре урын алган; анда шулай ук К.Насыйриның «Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы [башлангычы]» язмасы, мәгърифәтченең авылдашлары Гыйбадулла *Төхфәтуллин*, Талип *Гайсин*, Гыйльман *Ногманов*, Мәсхәпҗамал *Ибәтуллина*, Гатаулла *Дусаев*, дин эшлеклеләре Зыя *Бәхтияров*, Хатыйп *Алишевның*, әнисе ягыннан туганы Габделбарый Насыйров истәлекләре, М.Гайнуллин тарафыннан төзелгән библиографик белешмәләр китерелгән.



Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Профессор Н.И.Воробьёв мөхәррирлегендә рус телендә басылган җыентыкта М.Х.Гайнуллин, Н.К.Дмитриев, Н.И.Воробьёвларның шул ук мәкаләләре белән бергә, Казан университеты доценты Рабига *Хәкимованың* «Каюм Насыров как языковед», өлкән фәнни хезмәткәр Хәйри *Гыймадинның* «О трудах Каюма Насырова в области собирания историко-археологических материалов», профессор Фатих *Мөхәммәдъяровның* «Каюм Насыров как популяризатор медико-санитарных знаний среди татар» язмалары, М.Гайнуллинның «Каюм Насыров в документах» дигән тагын бер мәкаләсе урнаштырылган.

Чыг.: Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары) / җав. ред. Ш.А.Рамазанов. Казан, 1948; Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвященных 120-летию со дня рожденя) / отв. ред. Н.И.Воробьев. Казань, 1948.


Әд.: Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык Казан, 2017.

Р.Ф.Исламов.

«КАЮ́М НАСЫЙРИ́: ӘДӘБИ́-ТАРИХИ́ ҺӘМ ДОКУМЕНТА́ЛЬ-БИОГРА́ФИК ҖЫЕНТЫ́К», Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле, аның якын даирәсе һәм эшчәнлегенә багышлана. 2017 елда Җәүдәт *Миңнуллин* фәнни мөхәррирлегендә Рәмил Исламов тарафыннан төзелә.

Китапка К.Насыйриның матур әдәбият әсәрләреннән «Әбугалисина кыйссасы», Оренбургка сәфәре уңае белән язылган «Сәфәр» истәлек-юлъязмасы, әхлак темасына багышланган «Тәрбия китабы»; фәнни хезмәтләреннән татар укымышлылары хакында мәгълүматы, *Археология материаллары* (*Зөя өязендәге авыллар буенча*), «*Казан татарларының ислам диненә кадәр булган ышанулары һәм йолалары*» төп нөсхәләрдән алынып, тулы тексты урнаштырылган. Анда шулай ук мәгърифәтченең тормышын һәм күп кырлы эшчәнлеген яктырткан уникә тематик мәкалә бирелә. Туганнары, авылдашлары, аны күреп белгән һәм үзе белән турыдан-туры аралашкан кешеләр тарафыннан язылган 23 ис-

тәлекнең 12 се гарәп хәрефләреннән гамәлдәге татар графикасына күчерелеп, укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Җыентыкта К.Насыйриның әти-әнисенә, туганнарына һәм башка кешеләргә язган хатлары, шулай ук аның үзенә язылган, нигездә, гарәп хәрефләрендәге төп нөсхәләрдән алынган 220 хат тупланган, шуларның 163 е шулай ук беренче тапкыр дөнья күрә (кара: *Каюм Насыйриның хатлары*). Биредә 21 дәгъватнамә (чакыру) китерелә, алар Каюм Насыйриның аралашу даирәсен яңача күзалларга мөмкинлек бирә.



Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017.

Җыентыкта К.Насыйрига кагылышлы төрле документлар тәкъдим ителә, шулар арасында аның 1898 елгы пасporты, укытырга балалар туплавы хакында белдерүе, Казан университеты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең* хакыйкый әгъзасы дипломы, хисап кәгазьләре, үзе тарафыннан рус телендә төзелгән кайбер хезмәтләренең исемлеге, 1922–1925 елларда Татарстан Мәгариф халык комиссариатында аңа бәйле мәсьәләләр каралган 6 утырыш беркетмәсе урын алган (тулырак кара: *Гыйльми үзәк*).

Китапның ахырында К.Насыйриның һәм аның күпкырлы хезмәтен өйрәнүчеләрнең тулыландырылган библиографиясе урнаштырыла.

Чыг.: Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017.

Әд.: Мозаффар Э. Каюм Насыйрига мәңгелек һәйкәл // Шәһри Казан. 2018. 3 июль.

Р.Ф.Исламов.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ БҮЛӘГЕ́, исемле бүләк. 1988 елда ТАССР Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясе һәм РСФСР Педагогия җәмгыятенең ТАССР бүлеге президиумы карары белән гамәлгә куела; шул ук вакытта аның нигезләмәсе һәм әлеге бүләккә тәкъдим ителгән эшләрне карау һәм бәяләү буенча комиссия составы раслана. Тәрбия һәм укыту өлкәсендәге яңа хезмәтләр, татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты укытуда алдынгы педагогик тәҗрибә туплау һәм аны тормышка ашыруга, республикада халык мәгарифен үстерүгә зур өлеш керткән өчен укытучыларны, мәгариф һәм фән хезмәткәрләрен бүләкләү, шулай ук шәхси хезмәтләр белән бергә педагогик советлар, җәмәгать оешмалары, галимнәр һәм методистлар тәкъдиме белән күмәк хезмәтләрне дә кабул итү карала.

ТР Министрлар Кабинетының 113 нче 2005 ел 4 март карары белән республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгына ел саен К.Насыйри исемендәге ике бүләк тапшыру — педагогик коллективларны 70 мең сум, мәктәпкәчә, өстәмә, гомуми урта, башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем оешмалары хезмәткәрләрен 35 мең



сум күләмендә бүләкләү хокукы бирелә.

Бүләк лауреатлары арасында галимнәр Р.Ф.*Исламов*, Ә.Н.*Хәйри*, Р.Ә.*Шакиржанов*, А.Г.*Яхин*; Казандагы 149 нчы лицей, 167 нче мәктәп, 4 нче, 20 нче, 27 нче, 155 нче гимназияләр, 67 нче балалар бакчасы, Бөгелмә шәһәрендәге 14 нче гимназия, Мамадыштагы «Әкият» балалар бакчасы, Яшел Үзәндәге 10 нчы гимназия, Чаллыдагы «Бәләкәч», «Көнбагышкай», «Камыр батыр», «Шатлык» балалар бакчалары, Зәйдәге һәм Мөслим авылындагы «Кояшкай» балалар бакчалары, Биектау районы Ямашырмә авылындагы «Йолдыз» балалар бакчасы, Лаеш районы Кече Елга авылындагы мәктәп һәм башка шәхесләр, коллективлар бар. Кара: *Кушымта 1.*

Әд.: Каюм Насыйри исемендәге премия // Казан утлары. 1988. № 10; Каюм Насыйри премиясе лауреатлары // Казан утлары. 1998. № 5.

И.Х.Хәлиуллин.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ ИНСТИТУТЫ́, фән һәм белем бирү үзәге; Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының төп структур берәмлеге. ТР дәүләт телләрен һәм ТРда башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү дәүләт программасы (2014–2020) кысаларында Казан федераль университеты Гыйльми советының 2014 ел 7 февраль карары белән оештырыла.


Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрының
2005 нче елның 16 нчы мартында чыгарылган
267 нче боерыгы нигезендә

Татар мәгарифен үстерү һәм камилләштерүдәге
лаеклы хезмәтләре өчен

САБА РАЙОНЫ "ӘЛЛҮКИ"
МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ
УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
КОЛЛЕКТИВЫНА

КАЮМ НАСЫЙРИ
ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ БИРЕЛӘ

Премия Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты 1995 нче елның 19 нчы июнендә
кабул иткән 396 нчы карар белән билгеләнде

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм
фән министры Р.Ф.Шәйхелисламов

Казан шәһәре
2005 нче ел

На основании приказа № 267 от 16 марта 2005 года
Министра образования и науки
Республики Татарстан

За заслуги в развитии и совершенствовании
национального образования

КОЛЛЕКТИВУ ДОШКОЛЬНОГО
ОБРАЗОВАТЕЛЬНОГО
УЧРЕЖДЕНИЯ "ӘЛЛҮКИ"
САБИНСКОГО РАЙОНА

ПРИСУЖДАЕТСЯ ПРЕМИЯ
ИМЕНИ КАЮМА НАСЫРИ

Премия учреждена постановлением
Кабинета Министров Республики Татарстан
от 19.06.1995 г. № 396.

Министр образования и науки
Республики Татарстан Р.Ф.Шайхелисламов

Город Казань
2005 год

Серия КН 0045

Институтның төп максаты — Россия төбәкләрендә, чит илләрдә, гомумән алганда, бөтен дөньяда татар телен пропагандалау, Россия Федерациясендә татар телен һәм мәдәниятен, якын һәм ерак чит илләрдә татар һәм рус телләрен, мәдәниятләрен популярлаштыруны һәм үстерүне тәэмин итү, татар һәм рус халыкларының телләрен, традицияләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү мәсьәләләре буенча халыкка ярдәм күрсәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре — онлайн һәм офлайн форматта татар телен түләүсез өйрәнү курслары оештыру, институт үзәкләре методистларына мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтү, татар һәм рус телләрен, мәдәниятләрен популярлаштыруга юнәлтелгән конкурслар һәм мәдәни-агарту чаралары, фәнни-гамәли конференцияләр, фәнни-популяр онлайн лекцияләр, танылган татар язучылары һәм шагыйрьләре, галимнәр белән очрашулар уздыру һ.б.

Каюм Насыйри институты үз эшчәнлеге өлкәсендә шушы юнәлештә уңышлы эшләп килүче дөньякүләм атаклы Гёте һәм Сервантес институтлары, чагыштырмача яшь Конфуций һәм Юныс Әмре институтлары тәҗрибәсенә йөз тота һәм үзалдына шулар дәрәҗәсендә дөньяга танылу бурычын куя.

Хәзерге вакытта Россия һәм чит илләр шәһәрләрендә Каюм Насыйри институтының 15 мәгариф-мәдәният үзәге эшли: Мәскәүдә Муса Җәлил исемендәге 1186 нчы этномәдәни татар компонентлы белем бирү мәктәбе җирлегендә (2014 елдан); Казакъстанның Астана шәһәре Л.Н.Гумилев исемендәге Евразия милли университеты җирлегендә (2014); Санкт-Петербургта ТРның Санкт-Петербургтагы һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллеге җирлегендә (2015); Кыргызстанның Бишкәк шәһәре «Туган тел» татар-башкорт мәдәният үзәге җирлегендә (2015); Екатеринбург шәһәрендә ТРның Екатеринбург шәһәре һәм Свердловск өлкәсендәге даими вәкиллеге җирлегендә (2015); Уфа шәһәрендә М.Акмулла исемендәге Башкорт педагогика университеты җирлегендә (2016); Пенза шәһәрендә «Татар милли-мәдәни автономиясе» Россия иҗтимагый оешмасы җирлегендә (2016); Чабаксар шәһәрендә И.Н.Ульянов исемендәге Чуаш университеты җирлегендә (2017); Ульяновск шәһәрендә Ульяновск иҗтимагый татар милли-мәдәни автономиясе җирлегендә (2018); Тобол шәһәрендә «Себер-татар мәдәният үзәге» муниципаль автоном мәдәният оешмасы җирлегендә (2019); Самара шәһәрендә «Дуслык» төбәк татар иҗтимагый оешмасы җирлегендә (2020); Пермь краеның Барда авылында «Барда районы татар-башкорт мәдәни үзәге» иҗтимагый оешмасы җирлегендә (2021); Үзбәкстанның Ташкент шәһәрендә М.Улугбәк исемендәге Милли университет җирлегендә (2022); Әзәрбайҗанның Баку шәһәрендә ТРның Әзәрбайҗандагы даими вәкиллеге җирлегендә (2023), Беларусьның Минск шәһәрендә Белорус технология университеты җирлегендә (2024). Барлык үзәкләр дә дәреслекләр, уку-укыту ярдәмлекләре, танып белү әсбаплары, шулай ук матур әдәбият белән тәэмин ителгән.

Институт тарафыннан үткәрелә торган чаралар Казан федераль университеты сайтында, шулай ук ТР, РФ һәм чит илләрдәге мәгълүмат чараларында яктыртып барыла. Аларда ел саен 9 меңнән артык кеше катнаша.

Институт телләр күптөрлелеген саклауга керткән өлеше өчен Бөтенроссия «Төп сүз» («Ключевое слово») премиясенә лаек була (2017). 2016 елдан директоры – Ә.Ш.*Юсупова.*

Ә.Ш.Юсупова.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ КАЛЕНДАРЬЛАРЫ́, китап рәвешендә төзелгән еллык басмалар. Каюм Насыйриның беренче 1871 елгы календаре 1870 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә. Әлеге басмадан башлап 1898 елга кадәр 24 тапкыр бастырыла. 1886, 1887, 1895 еллардан гайре, алар һәр елны басылып киләләр. Календарьларның барысы да (1883 елгысыннан тыш — *Перов И.С. ташбасмаханәсендә*) Казан университеты басмаханәсендә хәреф җыю ысулы белән эшләнеп басылалар. Башта алар Ибраһим Абдуллин, Мөхәммәтҗан Мифтахетдин угылы, Мөхәммәтнәҗип Галиәкбәр угылы, Шаһиәхмәт *Биккиниев* матди ярдәмендә басылып, алга таба Каюм Насыйри аларны үз хисабына чыгара башлый.

Календарьларның тышлыгы күпчелек очракта орнаментлар, төрле рәсемнәр белән бизәлгән. Алар арасында Сөембикә манарасы, Казан мәчетләре рәсемнәре бар, шулай ук аерым басмаларның текстында геометрик орнаментлар урын алган. Кайбер елларда тышлыкларның бер өлеше алтынсыман, алардагы рәсемнәр исә төсле буяулар белән басылган. Аларның барысы да Перов ташбасмаханәсендә нәшер ителгән. Татар басма китабы тарихында рәсемнәрне төрле төсләр белән басу очрагына без беренче булараК К.Насыйри календарьларында тап булабыз.

Басманың максатыннан күренгәнчә, календарьларда вакыт берәмлекләре турында белешмәләр китерелә. Алар һәр чыгарылышның нигездә 12 сәхифәсендә урын ала. Көннәр хәзерге исемнәрдә бирелә. Беренче календарьларда кояш чыгу, кояш баю, таң белену, икенде (төштән соңгы вакыт), ястү (эңгер-меңгер вакыт) вакытлары күрсәтелә. Кайсы көннәрнең мөхәкамсез (гадәти), кайсы көннәрнең мөселман дине буенча «бәйрәм вә тәбрик көннәр» булуы билгеләнә. Ай, кояш тотылу турында тулы мәгълүмат урнаштырыла. Мәсәлән, 1872 елгы календарьда болай диелгән: «Май унберендә айның берничә микъдары тотылыр, төн уртасыннан соң, 1 сәгать 11 минутта тотыла башлап 2 сәгать 25 минутка чаклы булыр. Россиядә һәм күренер. Май 25 ендә кояш тотылыр, алка рәвешендә булып. Иртә белән 6 сәгать 31 минутта тотыла башлап 7 сәгать 49 минутка чаклы булыр. Бездә күренмәс. Азиядә һәм Мөхит диңгезендә (Тын океанда) күренер».

Басма башлыча Кояш календаре, ягъни милади, Россиядә Пётр I заманында кабул ителгән календарь нигезендә төзелгән. Шул ук вакытта һәр елны аерым таблицаларда теге яки бу милади елның кайсы һиҗри елга туры килүе, ул һиҗри елның кайсы айның кайсы көненнән башлануы кебек мәгълүматлар бирелә. Шулар белән берәттән Шәрекътә яшәп килгән хайван циклы календаре да китерелә (сыгыр елы, барс елы, сычкан елы һ.б.). Шулай ук һиҗри еллар айларының да исемнәре атала: рамазан ае (Ай елының тугызынчы ае исеме), сәфәр ае (Ай елының икенче ае исеме), рәҗәп ае (Ай елының җиденче ае исеме)... Шулай итеп, К.Насыйри календарьлары берьюлы өч төрле календарь белешмәләрен эченә ала. Әгәр Россиядә мондый характердагы белешмәләр чыгарылмаганын исәпкә алсак, аның өч төрле календарьны берләштерү, бергә туплау кебек шактый катлаулы эш башкарганын ачык күрербез. Хайван циклына кергән еллар календарен ул «Казакъ календаре» дип атый, андый календарь малчылык, хайван үрчетү белән көн күргән халыкларда булган, дип билгеләп үтелә.

Календарьларда К.Насыйри айлар, көннәр белән берәттән йолдызнамә

(гороскоп) рәвешендә белешмәләр дә китерә. Шуннан бер-ике үрнәк: «Май аенда туган бала үпкәчән, ачучан һәм зәгыйфь табигатьле булыр, үлмичә 31 дән узса, 80 яшенәчә гомер итәр», «Сентябрьдә туган бала гыйлем вә хөкүмәткә рәгъбәт (омтылу) итүчән [булыр] ... көнчелек кылучылары күп булыр, әгәр 35 яшендә әҗәл итмәсә, 85 кә чаклы гомер итәр...». Аерым айларга йолдызнамәләр биреп килү календарьны җанландыру максатын күздә тотып эшләнгән булса кирәк.

Милади календарьда теге яки бу айның ничек киләчәгә турында фаразлар да китерелә. Мәсәлән, «1872 елның сентябрендә бераннан 7 сенәчә томан-яңгыр. 7 сендә бик җил, 12–14 ендә аяз һәм җылы, 23 ендә аяз, әмма кичләрен салкын, 31 еннан ары җилле һавалар...» булачагы әйтелә.

Хайван циклына кергән еллар турында да К.Насыйри белешмәләр китерә. Менә шуларның берсе: «1890 — барс елы килсә, ул ел кыш тереклеккә суык булгай, барча җирләр кыш катыгъ булгай, сәйедләр (аксөякләр, хөкемдарлар), казыйлар күп үлгәй, такый (әмма) ашлык күп булгай, очсызлык булгай, ул ел угыл-кыз туса, хәтәрлек булгай».

К.Насыйри календарьларының вакыт күрсәткечләре рус телендә чыккан календарьларга нигезләнгән, ләкин биредә дә ул аларны кабатлау белән генә чикләнми. Өч төрле календарь күрсәткечләрен бирү үзе үк шул турыда сөйли. Шуның өстенә аның календарьларында кояш чыгу, баю вакыты кебек мәгълүматлар Казанның географик меридианы буенча бирелгән. Ул елларда Казан вакытын күрсәткән календарьлар булмаган. Бу вакытны К.Насыйри үзе билгеләгән. Казан, Кострома, Оренбург һәм башка шәһәрләрдә астрономик дөрес вакытны билгеләү өчен китергән аңлатмалары, хронометр, карта ярдәмендә кояш торышын билгеләп, вакытны ачыклауга багышланган материаллары К.Насыйриның *астрономия* өлкәсендә дә заманы өчен гаять тирән белемле галим булуын раслыйлар.

1877 елга кадәр К.Насыйри үзенең календарьларын «Казан календаре» дип, 1878 елдан соң бары «Календарь» дип кенә атый. Моңарчы анда вакыт Казан меридианы буенча күрсәтелсә, 1878 елдан соң вакытны төрле урыннарда ни рәвешле төгәл билгеләү турында аңлатма һәм аңа өстәп карта да бастырылгач, аның календарьларын бу җәһәттән башка урыннарда да куллану мөмкинлеге туа. Димәк, «Казан» дигән билгеләмәнең кирәге калмый.

К.Насыйриның 1883 елгы календарьда чыккан Кояш системасы, планеталар, ай, кояш тотылу турындагы гаять тәфсилле, схемалар белән дә баетылган фәнни-популяр мәкаләсе аның дөньяга карашын билгеләүдә гаять зур әһәмияткә ия.

Беренче карашка гади күренгән менә шундый белешмәләр бирүне дә К.Насыйри халык арасында фәнни белемнәр тарату өчен оста кулланган. Календарь материалларының газеталарда шактый киң яктыртылып килүе безнең көннәр өчен дә ят нәрсә түгел. Шуннан чыгып, К.Насыйри календарьларының бу юнәлештә дә вакытлы матбугатка тартымлылыгын расларга мөмкин.

1872 ел өчен чыгарылган календарьда К.Насыйри: «Инде бу заманда һичкемгә мөмкин түгел «мин закон белмим», дип котылырга. Кирәк урыс булсын, кирәк башка төрле халык булсын, Русиядә торганда законны белергә тиеш. Хөкемгә баргач һичкем әйтмәсен, «мин бу эшне закон белмәгәнлектән эшләдем», дип. «Закон белмим», дип әйткән сүзне һич кабул итмәсләр», — дип төшендерә. Һәм шул

уңайдан 1864 елның 20 ноябрендә гамәлгә кергән гражданлык-процессуаль кодексның төп нигезләмәләре белән таныштыра, «мировой судья», «поверенный», «дәгъвачы исбат кыйла торган эшләр», «мировой судья чакыру», «окружной суд», «судебная палата», «мөселманнарның судта ант бирү тәртипләре» кебек төшенчәләрнең мәгънәләрен аңлата. Шуңа охшаш мәкаләләр башка еллар календарьларында да тулыландырылып, күпчелек очракта яңа шәрехләр белән баетылып басыла.

1872 елда чыккан календарьда 1870–1871 елларда кабул ителгән «Городовое положение», бер катлаудан икенче катлауга күчү турында, училище укытучыларын солдатка алмау, сары билет белән кайткан солдатларга никахлашу өчен рөхсәт сорауның кирәге юклыгы, иске акчаны бетерү һәм башка законнар турында белешмәләр бирелә. 1875 елгы календарьда хәрби хезмәткә алу турындагы законның төп маддәләре һәм бу закон турында аңлатмалар урнаштырылган. К.Насыйри календарь укучыларны яңа чыккан законнар белән ел саен шулай таныштырып килә.

1889, 1890, 1892 һәм башка ел календарьларында К.Насыйри Оренбург мөселман Мөхкәмиягә (дөрес хөкем урыны) әгъза булып керү, ахунлыкка, хатиплыкка (мәчеттә вәгазь укырга хаклы мулла), «казакъ гаскәрләрендә» — армиядә муллалыкка ничек сайлану, мәдрәсәдә укыту өчен нинди имтиханнар бирергә кирәклеге һәм башкалар турындагы хөкүмәт карарларының һәм законнарның нигезләмәләре белән таныштыра. Аларда шулай ук яңа йорт, каралты салу тәртипләре, «Ут-хәвефтән саклану тәртибе» (1884 ел календаре), «Легковой һәм ломовой ямщиклар өчен низам (закон, тәртип)» (1873 ел календаре), Казанның бер урыныннан икенче урынына алып бару бәяләре кебек материаллар урнаштырыла.

Календарьларда урын алган законнар арасында сату-алу эшенә караганнары да аз түгел. Тәүге календарьда ук «Сәүдә хосусында низамнар» басыла. 1873 елгысында «сату итүнең правасы бәянында» дигән күләмле аңлатма урнаштырыла. Анда төрле маллар белән сәүдә итү һәм аның формалары, китап кибете тоту, даруханә ачу, теге яки бу дәрәҗә (гильдия) сәүдәгәр булу өчен ниләр кирәклеге турында һәм башка белешмәләр китерелә. «Сәүдә хәлләре, сәүдә маллары» (1880) белешмәсендә Россия законнары буенча чит илләргә сату өчен нинди товарлар алып чыгарга һәм илгә нинди товарлар кертергә рөхсәт ителү, чит илгә бару өчен паспорт алу, чит илгә акча җибәрү тәртипләре, сәүдә пошлинасы, Дәүләт банкы һәм башкалар хакында мәгълүматлар, аңлатмалар бирелә.

Дәүләтнең югары органнары, департаментлары, министрлыклары белән дә таныштыру халыкка мөһим булган. 1875 елгы календарьда К.Насыйри Сенат, Галиҗәнапның үз канцелярисе, министрлыклар, аларның төп функцияләре, алар башында кемнәрнең утыруы турында кулланма бирә.

К.Насыйри һәр календарьда диярлек элемтә, аралашу кагыйдәләре белән таныштырып килә. «Пушты бәянында» белешмәсендә «пичәтле хат», «ачык хат», «заказ хат», «бандероль», «посылка», «кыйммәтле посылка», «акчалы пакет», чит илләргә хат җибәрү, телеграф һәм аннан ничек файдалану тәртипләре күрсәтелә. 1880 елгы календарьда Россиядәге тимер юл челтәре, төрле тимер юл линияләре, алардагы станцияләр, аерым шәһәрләрнең ераклыгын күрсәткән мәгълүматлар китерелә.

Гомуми һәм татарларга карый торган законнар, нигезләмәләр белән даими таныштырып бару, илдәге дәүләт аппараты системасы турында белешмәләр, элемтә-почта хезмәте турындагы кагыйдәләрне белү халыкның тормыш-көнкүреше өчен кирәк булган. Бу төрдәге материалларны бирү — вакытлы матбугатка да хас күренеш. Димәк, бу яктан да К.Насыйри календарьлары матбугат чараларына якын торган.

Сәүдә мәсьәләсенә караган закон-низамнардан тыш, һәр календарьда бөтен Россия күләмендә кайсы көннәрдә, кайсы шәһәрләрдә ярминкәләр үткәрелү турында белешмә бирелә, кайбер елларда Казаннан ерак булмаган районнарда нинди базарлар булуы хәбәр ителә.

1893 елгы календарьда К.Насыйри Мәкәржә ярминкәсе турында тарихи очерк та бастыра. Аның башлап Казанда ачылуы, Казан ханлыгындагы бу ярминкәнең даны киң таралуы: Кытай, Һиндстан, Көнбатыш Европа, Мәскәү, Казан сәүдәгәрләренең очрашу урыны булуы хакында языла. Шул уңайдан мәгърифәтче календарьда Мәкәржә ярминкәсендә сату тәртипләре турындагы хөкүмәт нигезләмәләренең дә тәрҗемәләрен бирә.

Мәгълүм булганча, вакытлы матбугат басмаларында укучыларны фән, техника, мәдәният яңалыклары белән таныштыруга да зур әһәмият бирелә. Әлеге үзенчәлек К.Насыйри календарьларында да күренә. Календарь битләрендә даими рәвештә географиягә, тарихка караган мәкаләләр, химия, технология, астрономия, этнография буенча белешмәләр басылып тора.

Географиягә караган материалларның күпчелеге Россиягә багышлана. 1872, 1873 елгы календарьларда Россиянең иң зур мәмләкәтләрдән булуы, анда нинди халыклар яшәве, иленең географик зоналары, елга, диңгезләре, урман-таулары, казылма байлыклары, аңа күрше дәүләтләр турында һәм башка күп кенә мәгълүматлар китерелә. «Россиядәге губерналар» белешмәсендә һәр губернада күпме кеше яшәвен, аның төп шәһәре Казаннан ничә чакрымда булуын күрсәткән таблицалар урнаштырылган. 1872 елгы календарьда Казан губернасында 1 607 122 кеше яшәве күрсәтелә. Географик белешмәләрдә, сугыш була калса, Россиянең күпме солдат чакыра алуы, илдә күпме алпавыт, рухани, сәүдәгәр, чиновник һ.б. турында да таблицалар бар. Россиядә яшәүче халыкларның дин, милләт буенча бүленеше дә бирелгән. Календарьдан Россиянең 1870 елда чит илләргә күпме чимал чыгаруын, чит илләрдән күпме шикәр, чәй, кahвә, мамык, пыяла, кургашын, мануфактура кебек материаллар сатып алуын да белергә мөмкин.

1880 елгы календарьдагы «Русия» мәкаләсе илнең икътисади географиясенә карый. Анда Россиянең территориясе, барлыгы 95 миллион кеше яшәве, аларның 40 төрле телдә сөйләшүе, ел саен күпме кешенең тууы һәм үлүе, никадәр алтын казып алыну, күпме уңыш җыелу, илдә барлыгы ничә мәктәп, уку йорты, күпме укучы булу һ.б. турында кызыклы гына мәгълүматлар тупланган.

Календарьларда К.Насыйри чит илләр географиясен яктыртуга да шактый зур урын бирә. 1875 елгы календарьда җир йөзендә барлыгы 1 341 000 000 кеше яшәве, халыкларның аерым кыйтгалар һәм зур дәүләтләр буенча бүленеше күрсәтелә. Шул таблицалардан күренгәнчә, ул чорда Лондонда — 3 214 620, Парижда — 1 851 896, Венада — 834 000, Берлинда — 864 000, Петербургта — 687 963, Мәскәүдә 611 970 кеше яшәгән.

1873–1876 елгы календарьларда «Ят мәмләкәтләр хосусында» исеме белән Австрия, Бельгия, Бразилия, Англия, Германия, Пруссия, Италия, Персия һәм башка дәүләтләр турында белешмәләр урын алган. Аларда дәүләт башында утыручы император, патшаларның исемнәре белән берәттән илнең икътисады, халкы, армиясе, кереме кебек мәсьәләләр буенча да мәгълүматлар бирелгән.

1885 елгы календарьда — Урта Азия («Мәмләкәте Төркестан»), 1891 елдагысында Төркия турында тарихи-географик очерклар урнаштырылган. 1877 ел календаренда Азия, Африка, Америка дәүләтләре турында кыскача белешмәләр урын алган.

К.Насыйри Россия тарихын яктыртуны, пропагандалауны да игътибар үзәгенә алган. 1872 елгы календарьда урнаштырылган «Русия тарихыннан берничә сәхифә», «Мәскәү мәмләкәте» дип аталган хезмәтләр рус тарихчысы Н.Г.Устряловтан тәрҗемә ителгәннәр. 1872, 1873 елгы календарьларда — «Хәтердә тотарга тиешле бәгъзе вакыйгалар», 1891 елдагысында «Рус тәварихыннан хәтердә тотарга лаеклы вакыйгалар», «Рус мәмләкәтенең тәрәкъкыйәте» дигән исемнәр белән тарихи хронологияләр китерелгән. Аларда Россиядә беренче алфавит кабул ителү, академия салыну, китап баса башлау, беренче тимер юл төзелү кебек әһәмиятле тарихи фактлар белән бергә кайсы территорияләрнең кайчан Россиягә кертелүе дә күрсәтелә.

1882 елгы календарьның төп өлеше дөньякүләм-тарихи хронологияне хәтерләтә. Анда нинди генә белешмәләр юк. Александр Македонский, Аристотель, Сократ, Мөхәммәд пәйгамбәрдән алып соңгы көннәргә кадәрге атаклы кешеләр, «Җир белән күк арасында вә җир йөзендә» булган гаҗәеп хәлләр, табигатьнең гайре күренешләре, тарихта теркәлгән һәлакәтләр исемлеге... Шулардан берничә мисал: «307 (919) елда [башта һиҗри, аннан милади ел күрсәтелә] һавадан бер йолдыз иңеп... җир йөзен яктылык тотты, һавада болыт асла (һич) юк иде, күк күкрәгән кебек олуг вә куркыныч авазлар ишетелде»; «434 (1046) елда Тәбриздә бер олуг зилзилә булып, бөтен шәһәр вә хазалар йоклап биналар җир астында калды, 150 меңләп халык һәлак булды...»

К.Насыйри календарь битләрендә татар халкының тарихы, теле, аларның килеп чыгышы буенча да материаллар урнаштыруга зур игътибар биргән. 1877 елгы календарьда Казан һәм Уфа губерналарында ничә өяз булуы, аларның исемнәре, аларда күпме мөселман яшәве әйтелә, бу өязләрнең демографик күрсәткечләре китерелә. Мәгърифәтче галимнең Оренбургка баруы тасвирланган «Сәфәр» сәяхәтнамәсе (1894 елгы календарь), татар халык легендалары буенча язылган «Алып адәмнәр» хезмәте (1883), шулай ук «Казан шәһәрләрендәге мәҗедләр» (1882), болгар бабаларыбыз турындагы белешмәләр (1885), Казан ханнарының хакимлек иткән еллары һәм исемнәре (1873), халкыбыз тарихы буенча әһәмиятле чыганак булараклар, хәзер дә кызыксыну уята. Гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белгән К.Насыйри телебезнең сүзләргә гаять бай, грамматикасы белән камил булган иң алдынгы телләрдән бер ягы белән дә ким түгеллеген, бу телдә күп сандагы әдәби, фәнни хезмәтләр язылуын ассызыклый (1885). 1893 елгы календарьда татар укучылары өчен хат язу үрнәкләре китерелеп, аларга телнең һәм аның стиленең бай мөмкинлекләреннән файдалану юллары күрсәтелә.

Календарь битләрендә галим үзе җыйган татар фольклоры материал-

ларына да урын биргән. Алар арасында «Казан бәете», «Шаһгали бәете», Кабан күле турындагы легендалар белән беррәттән «Кояш кызарып чыкса яки кызарып баеса — җил булыр», «Кояш баегач томан яки болыт булса, иртән яңгыр булыр», «Имән чикләвеге күп булса, кыш җылы булыр» кебек сынамышлар да бар. Фольклор әсәрләреннән үрнәкләр, халык тәҗрибәсен чагылдырган материаллар бирү — газеталар өчен гадәти күренеш. Ул заманда аның әһәмияте календарьны кызыклы итеп чыгару белән генә чикләнми. Әлеге материаллар кешеләрдә халык иҗаты белән кызыксыну тудыруга, шулай ук аны туплауга этәргеч тә булганнар.

Календарьларны К.Насыйри халык арасында яшәп килгән им-том, ырымнар белән көрәшү, медицина буенча фәнни белемнәр тарату өчен дә киң файдалана, санитария, гигиена, дарулар, аптекалар, дару үләннәре турында мәгълүматлар китерә. 1885, 1888 еллар календарьларында 500 гә якын дару үләненең татарча, гарәпчә, русча, латинча исемнәре күрсәтелгән. 1885 елгы календарьда медицинага караган мәкаләләрендә ул психотерапиянең әһәмияте турында яза. Алардан күренгәнчә, хәзерге вакытта да еш күзәтелә торган гиподинамия, стресс күренешләренең асылын галим яшәгән заманда ук инде яхшы аңлаганнар.

1873 елгы календарьда бит, кул, гәүдә-тән гигиенасы, тешне саклау һәм чиста тоту, биттәге җыерчыклар, сипкелләрне бетерү буенча нинди үләннәр, дарулар куллану, нинди санитария чараларын үтәү зарурлыгы аңлатыла. Чәчне матур тоту, аны коелудан, сирәкләнүдән саклый торган үлән төнәтмәсе рецептлары тәкъдим ителә. Алар халык медицинасыннан, Әбугалисина хезмәтләреннән алынган. 1873, 1889, 1890 елгы календарьларда аракы һәм тәмәкенең зыянын аңлаткан мәкаләләр дә урнаштырылган.

1873 елгы календарьда химиянең нинди фән булуы, аның тормыштагы роле турында сөйләнә. «Технологиядән берничә кәлимә (сүз)» исеме астында крахмал, хушбуй, лак, сургыч, сабын, серкә ясау ысуллары, киемдәге тапларны бетерү, 1873 ел календаренда көя, кандала, тараканнарны юк итү юллары күрсәтелә. Соңгысында шулай ук Россиядә кулланыла торган озынлык, авырлык, күләм үлчәүләре турында да мәгълүмат бар.

Календарьларда тәрбия, әхлак темасына да популяр материаллар басылып килә. Шулар арасыннан К.Насыйри җыентыкларына керми калган, 1892 елгы календарьда урнаштырылган «Китап әт-тәрбият» дип аталган дидактик киңәшләр циклы белән дә танышырга мөмкин. Анда К.Насыйриның тәрбия асылын аңлатуы аның гаять тирән белемле педагог-галим булуын күрсәтә. «Тәрбия дигән сүз балаларны ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, — ди ул, — бәлки ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын-фигылен ислах кыйлмак (үзгәртү), вә төзәтмәк, вә хайваннаттан чыгарып инсаният дәрәҗәсенә күтәрмәк, вә тәгълим бирмәк. Вә өйрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп-әркян (терәк) бирмәк мәгънәсендәдер». Мәгърифәтченең әлеге хезмәтендә 113 дидактик киңәш урын ала. Шулар арасында, мәсәлән, «Халык арасында берәүне вәгазь вә нәсихәт кыйлмак аның башына сукмак кебектер. Һичшиксез, ул кеше сиңа дошман булды, ул синең нәсихәтеңне тоту кая, хәтта синең һәлакәткә тарикъ (юл) эзләр. Халыкка суфилыгыңны күрсәткән булып белер-белмәс җирдә нәсихәт кыйлмак булып маташма» дигәне гыйбрәтле. К.Насыйри балаларда олыларга ихтирам, ризыкка хөрмәт тәрбияләү алым-

нарын, аларны «һөнәргә өйрәтмәк» ысулларын тасвирлый. Бала тәрбиясенә, гомумән, педагогикага караган киңәшләр, гыйбрәтле кыска хикәяләр календарьның педагогик юнәлештәге журнал функциясен дә үтәвен раслый.

К.Насыйри — татарлар арсында рус телен укытуның кирәклеген аклап чыккан мәгърифәтче. Ул үзенең шушы юнәлештәге карашларын календарьларында да пропагандалый. Рус уку йортларында, гимназияләрдә укытыла торган фәннәр турында яза, аларның программаларын бастыра (1892).

К.Насыйри календарь битләрендә татар телендә чыккан, шул исәптән үзе язган китапларның исемлекләрен дә күрсәтә. 1897 елгы календарьга кушымта рәвешендә басылган *«Игълан»*тә галим үзе язган, үз тәрҗемәсендә чыккан 63 китапның библиографик тасвирламасын бирә. Анда хәзерге фәнни библиографик тасвирламаларда кулланыла торган барлык элементлар чагылыш тапкан. Шулардан бер үрнәк: «Ысул җәгърәфия кәбир (зур). 205 сәхифәдән гыйбарәт. Фәкать Азия кыйтгасы бәянында бер китаптыр ки, бу китапта Азия кыйтгасы... бәян кыйлынды. Уку өчен хуш гыйбарәт вә мөфид (әһәмиятле) бер китаптыр. 1894 елда басылды. 1 сум 20 тиен».

Библиографик характердагы материаллар белән берәттән календарьларда К.Насыйриның татар телендә чыккан теге яки бу китапка анализы, бәяләмәсе дә очрый. 1885 елгы календарьда, мәсәлән, ул Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Болгариның Казанда татар телендә нәшер ителгән Болгар дәүләте тарихы турындагы хезмәтенә карата фикерләрен белдерә һәм татар тәнкыйте өлкәсендә бу юнәлештә дә тәүге адымнар ясаган галим буларак ихтирамга лаек.

Календарьга кергән материалларның күп өлеше — К.Насыйриның үз иҗаты, яки халык арасыннан язып алынган, аның тарафыннан эшкәртелгән әсәрләр. Россиядә, Җир шарында яшәгән халыкларның саны рус телендә чыккан фәнни һәм статистик басмалардан алынган. Тарих, география буенча материаллар рус галимнәре хезмәтләренә таянып язылган. Татар укучысының белем дәрәҗәсен исәпкә алып, алар аңа аңлаешлы итеп эшләнгәннәр.

Календарьда басылган материалларның чыганакларыннан күренгәнчә, К.Насыйри башкала матбугатын күзәтеп барган, Казанда, Петербургта, Мәскәүдә чыга торган китаплар хакында яхшы белгән; рус теле, әдәбияты, шулай ук илдәге иҗтимагый-сәяси, юридик яңалыклардан яхшы хәбәрдар булган, нәтиҗәдә, календарьлары әтрафлы мәгълүматлар белән баетылган. Аларда шулай ук икътисадка, тормышның башка өлкәләренә, төрле фәннәргә караган материаллар, хәбәрләр дә бар. Календарьларының халыкка аңлаешлы булуын тәэмин итү не күздә тоткан хәлдә материалларның күпчелеге халык сөйләменә якын телдә язылган.

Календарь төзү — күп көч һәм белем сорый торган ифрат катлаулы шөгыль. Әлеге төр басмада заман сулышы сизелә, файдалы киңәшләр белән берәттән тарих, үткән һәм хәзерге көн турында белешмәләр туплана. Ләкин календарь гади белешмә китабы гына түгел. Ул — үзенә күрә энциклопедик хезмәт. Югарыдан аңлашылганча, К.Насыйри календарьлары ул чорда татар *вакытлы матбугаты* ролен дә үтәгән, алар ярдәмендә әдип-галим халык арасында «аң-белем тарату эшләре» алып барган.

Әд.: Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // Насыйри К. Сай-

ланма әсәрләр. Казан, 1953; Кәримуллин Ә.Г. Каюм Насыйри календарьлары // Әйдә халыкка хезмәткә! Казан, 1985; Миңнуллина Л. Татар календарьлары тарихыннан // Казан утлары. 2001. № 7; шул ук. Календарные издания просветителя К.Насыри // Миннуллина Л. З. Татарские печатные календари XIX — начала XX. вв. Казань, 2015.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ МА́РКАСЫ, почта хезмәте өчен махсус түләү билгесе. 1952 елда СССР Элемтә министрлыгы тарафыннан мәгърифәтче галим Каюм Насыйриның вафатына 50 ел тулу уңаеннан чыгарыла. Номеры — СК 1279.



Каюм Насыйри маркасы.

Тасвирламасы: 26×36 мм зурлыктагы тешсыман читләр белән чикләнгән сары фонлы вертикаль турыпочмаклык. Аның уртасында К.Насыйриның Б.*Элминов* рәсеме буенча рәссам А.Завьялов эшләгән көрән төстәге сурәте урнаштырылган. Сурәтнең күкрәгенә «Каюм Насыри (Насыров)» дип язылган, өсте — рус телендә «50 лет со дня смерти выдающего татарского просветителя», аскы өлеше урта өлештән «40 коп.» (40 тиен) бәясе белән бүленгән «Почта СССР» сүзләре белән чикләнгән, мәгърифәтче вафатының 50 еллыгы күрсәтелгән язу астында сурәтнең өске сул почмагында — «1902», уң почмагында «1952» даталары куелган. Тиражы — 1 000 000 данә.

И.Х.Хәлиуллин.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ МӘКТӘБЕ́ («Каюм Насыйри исемендәге аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 80 нче татар-рус урта гомуми белем мәктәбе»), кара: *Сиксәненче мәктәп*.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ МУЗЕЙ́, Казанда. 2002 елның 2 февралендә ТР Милли музее филиалы буларак, Казанның тарихи Иске Татар бистәсендә ачыла. 19 йөз ахыры – 20 йөз башында төзелгән һәм яңадан торгызылган татар төзелеш сәнгате истәлеге булган бинада урнашкан. Бинаның беренчесен Каюм Насыйриның туганы Мөхәммәтбәдигъ *Хөсәенов* төзетә. Ул 1979 елда яна; 1991–1995 елларда торгызыла. 1997 елда музей янында К.Насыйриның «Гөлзар вә чәмәнзар» («Чәчәкләр һәм үләннәр») хезмәтенә мөнәсәбәтле «Хәтер бакчасы» булдырыла.

Музей комплексының гомуми мәйданы — 0,47 га, экспозиция мәйданы — 113 м^2; 373 саклау берәмлеге. Фәнни концепциясе авторы һәм музейның сәнгать проекты автордашы —



Казанда Каюм Насыйри музее.

аның беренче директоры Р.С.Хөснетдинова; бизәлеше ТР Милли музееның баш рәссамы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Ф.Ә.Зыязов остаханәсе тарафыннан башкарыла. Экспозициянең төп бүлекләрен К.Насыйригa, 19 йөз татар мәгърифәтчелеге фикере үсешенең төп этапларына,



Казанда Каюм Насыйри музее.
2 нче зал экспозициясенең гомуми күренеше.

Ш.Мәржани һәм Х.Фәезханов иҗатларына багышланган тарихи-биографик һәм мемориаль-көнкүреш әйберләре бүлекләре тәшкил итә. Экспозициядә К.Насыйриның кулъязмалары һәм басма хезмәтләре, мәдрәсәләр өчен төзегән дәреслекләре һәм татар халык авыз иҗаты әсәрләренең язмалары, аның турында истәлекләр, шәхси архивлардан фотосурәтләр урын ала. Бай этнографик коллекцияләр һәм көнкүреш әйберләре Казанның Иске Татар һәм Яңа Татар бистәләре һәм элеккеге Зөя өязе татар авылларының көнкүрешен чагылдыра (самовар, үтүк; фарфор савыт-саба, комганнар һ.б.). К.Насыйриның абзасы Габделхәй һәм аның улы Габделмәннең әйберләре, шулай ук бертуганының кызы — тел белгече һәм фольклорчы Х.*Насыйриянең* (Хөсәенованың) стена көзгесе, өстәл вазасы, фарфор пудра савыты, җилпәзәсе бар. Кыйммәтле экспонатлар арасында — К.Насыйри күчереп язган кулъязма китап, аның шәхси китапханәсеннән алты китап (шәхси мөһере белән), язучыныкы дип исәпләнгән сандык, таяк һәм хронометр-сәгать, Хөсәеновлар һәм Игъламовлар нәселеннән килгән 19 йөз ахыры – 20 йөз башындагы шәхси әйберләр (115 саклау берәмлеге), Казанның Иске Татар бистәсе (60 саклау берәмлеге) һәм Казан артының 19 йөз ахыры – 20 йөз башына караган көнкүреш әйберләре (90 га якын саклау берәмлеге), китаплар коллекциясе, шул исәптән мәдрәсәләр өчен гарәп һәм татар телләрендә язылган дәреслекләр (135 саклау берәмлеге) саклана.

Музейда 14 февральдә галимнең туган көне уңаеннан аны искә алу чаралары уздырыла, ел саен 20 августта каберенә зиярәт кылына. Аннан тыш музейда төрле юнәлешләр буенча тематик интерактив лекцияләр үткәрелә, алар файдалы үләннәрнең дәвалау үзлекләренә, татар фольклоры һәм андагы образлар тарихына багышлана. Җәй айларында музей бакчасында «Төрек утырулары» дип исемләнгән зур чара уздырыла. Анда К.Насыйриның



Казанда Каюм Насыйри музее.
Экспозиция фрагменты: галимнең бүлмәсе.

этнографик материалларына нигезләнгән 19–20 йөзләр татар уеннары, төрек мәдәнияте, җырлары, шигырьләре белән танышу мөмкинлеге була. Музейда кәгазь ясау буенча «Үз кулың белән кәгазь ясау» һәм татар эки-

ятләренә багышланган «Каюм Насыйриның могҗизалы дөньясы» дип исемләнгән битлек ясау остаханәләре эшли. Музей экспозицияләре буенча кунаклар өчен экскурсияләр уздырыла. Музей тарафыннан ел саен К.Насыйри музее (2 февраль) һәм Халыкара музей (18 май) көннәре оештырыла.

Әд.: Каюм Насыйри музее — Музей Каюма Насыри [буклет]. Казан, 2002; Каюм Насыйри музее // Казан утлары. 2002. № 4; Гилазов З.З., Айнутдинов Р.А. Музей К. Насыри: история создания и формирования коллекциии // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциколпедических исследований: сб. ст. итоговой науч. конф. научных сотрудников Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ. Казань, 2019. — Вып. 11; Хабибуллина Д.А. Создание музея Каюма Насыри в городе Казани (1979–1996 гг.) // Актуальные проблемы регионоведения и науковедения. Казань, 2022. Вып. 11.

И.Х.Хәлиуллин.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ УРАМЫ́, Казан шәһәрендәге тарихи Иске Татар бистәсенең үзәк урамы. Хәзерге Габдулла Тукай урамына һәм Түбән Кабан күле ярына параллель рәвештә төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка таба, Татарстан урамыннан башланып, Зәйни Солтан, Фатих Кәрим, Күнче урамнарын кисеп узып, Сафьян урамына кадәр сузыла. Башта Захарий һәм Елисавета чиркәвенә нисбәтле Захарий (Захарьевский) урамы дип атала. 1930 елда урамга Каюм Насыйри исеме бирелә.

Заманында Иске Татар бистәсендәге иң матур, төп урам санала. Анда татар аксөякләре, югары катлау руханилар һәм бай сәүдәгәрләр яши. 2013 елда Универсиадага әзерлек кысаларында шәһәрне төзекләндерү барышында җәяүләләр урамы итеп үзгәртелә, тарихи биналар реставрацияләнә, Иске Татар бистәсен тулыландыру максатында сакланмаган истәлекләр урынында шул чорга хас корылышлы берничә йорт төзелә.

Урамда урнашкан йортларның номерлары Татарстан урамыннан башлана. Так ягында: №3 — беренче һәм икенче гильдия сәүдәгәрләр Казаковлар йорты, архитектор П.В.Тихомиров проекты буенча классицизм стилендә 1853 елда төзелгән ике катлы кирпеч бина; № 5 — беренче һәм икенче



Каюм Насыйри урамы. 1950 еллар.

гильдия сәүдәгәрләр Кушаевлар йорты, архитектор П.В.Тихомиров проекты буенча 1862 елда төзелгән ике катлы кирпеч бина; № 11–13 — икенче гильдия сәүдәгәр һәм җәмәгать эшлеклесе Борһанетдин Муллин йортлары, 19 йөзнең 2 нче ярты сында төзелгән ике катлы ярымташ йорт һәм бер катлы агач флигель; №15 — «Мәрҗания» мәдрәсәсе бинасы, 1881 елда төзелгән (хәзер — Казан ислам көллияте); №17 — «әл-Мәрҗани» мәчете (Беренче мәчет, Юнысов мәчете), архитектор В.И.Кафтырев проекты буенча, барокко һәм милли бизәлеш сәнгате элементлары кушылып, Россия патшабикәсе Екатерина II нең шәхси рөхсәте белән 1766–1770 елларда төзелгән ике катлы кирпеч бина; №27 — Апанай (Апанаев) мәчете (Икенче мә-

чет, «Байлар мәчете»), архитектор П.И.Романов проекты буенча, бароко, борынгы рус бизәкле архитектурасы һәм милли бизәлеш элементлары кушылып, сәүдәгәр Якуб Солтангалиев акчасына 1768–1771 елларда төзелгән өч катлы кирпеч бина; №33 — Исәнбаевлар йорты, 1880 елда төзелгән ике катлы ярымташ бина. Урамның җәп ягында: №10 — Шиһабетдин Мәрҗани йорты, атаклы галим яшәгән һәм вафат булган, классицизм стилендә 1858 елда төзелгән ике катлы ярымташ бина; №12 — классицизм стиле элементлары кергән тәрәзә йөзлекләре сакланган, 19 йөзнең 2 нче яртысында төзелгән бер катлы агач бина; №24 — сәүдәгәр Юнысовлар йорты, архитектор П.Т.Жуковский проекты буенча классицизм стилендә 1858 елда төзелгән ике катлы кирпеч бина; №38 — филолог Я.Х.Агишев йорты; №40 — икенче гильдия сәүдәгәр, хәйрияче Җиһанша Усманов (1817 елда туган) йорты, архитектор А.И.Песке проекты буенча классицизм стилендә 1853 елда төзелгән ике катлы кирпеч бина.

Әд.: Хәйруллин Ә., Әмирханов Р. Каюм Насыйри исемендәге урам // Социалистик Татарстан. 1985. 8 февраль; Казань: исторические районы, слободы, улицы, площади и парки: иллюстрированный энциклопедический справочник. Казань, 2021.

И.Х.Хәлиуллин.

КАЮ́М НАСЫЙРИ́ ЯШӘГӘ́Н ЙОРТЛА́Р, Каюм Насыйриның вакытлыча яшәү урыннары. Казанда хосусый йорт-җире булмау сәбәпле, галим еш кына бер йорттан икенчесенә күченеп яшәргә мәҗбүр була.

1841–1855 елларда «Касыймия» мәдрәсәсендә укыган вакытта яшәгән урыннары әлегә ачыкланмаган. 1855–1865 елларда *Казан өяз руханилар училищесында, Казан руханилар семинариясендә* укыткан вакытта семинариянең чардагында яши. 1865 елда, Мөсәгыйть ямщикның Зөһрә исемле кызына өйләнеп, алар йортына күченә. Хатыны вафатыннан соң (1866) 1873 елда Фукс урамында, аннан соң Захарьевский урамындагы Шиһаб хәзрәт мәхәлләсендә, Екатерининский урамындагы Ядгәр Шаһи (Ядгәр Ишимов) йортының өске катында, хәзерге Мәрҗани һәм Зәйни Солтанов урамнары чатында урнашкан Вәли бай йортында яши. 1879 елда Тихвин (хәзер — Тукай) урамында Госмановлар мәчетеннән берничә йорт аша торганлыгы мәгълүм. 1885 елда 2 нче гильдия сәүдәгәр *Мусин Гайса йортында* (элекке Поперечно-Сенная, хәзерге Париж Коммунасы урамы, 24) яши. Анда янгын вакытында аның күп кенә китаплары һәм кулъязмалары юкка чыга. Мәсәлән, «Гөлзар вә чәмәнзар» китабының шактый битләре утта өтелгән бер нөсхәсе хәзерге вакытта Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә* саклана. Шуннан соң ул, туган авылына кайтып, анда өч ай чамасы тора. Кабат Казанга килгәч, кардәше Бәдигъ мөәзин йортында алты ай яши. 1890–1891 елларда Тихвин һәм Евангелистлар урамнары чатындагы печән үлчәве каршында Чуаш иле Хәсән йортында, 1891–1892 елларда бер кыш Захарьевский урамы башындагы Сөләңгәр Камали йортында тора. 1892 елның көзендә исә яңадан туганы Мөхәммәтбәдигъ *Хөсәенов* йортына күченә.

1893 елның көзеннән башлап, сәүдәгәр Сөләйман *Аитов* карамагындагы агач өйдә (хәзерге Тукай урамында булган 45 нче ул йорт сакланмаган) яши. Аннары абыйсы Габделхәй нең улы Габделмән Казанский өендә

(хәзерге Галиәсгар Камал урамы), Кызыл мәчет урамында Әптелмән йортының кечкенә бер бүлмәсендә яшәве билгеле. Үзенең бер хатыннан күренгәнчә, ниндидер Чыршы Габди һ.б.ның йортларында гомер кичерә. 1899 елдан туганы Мөхәммәтбәдигъ мөәзин өенең (хәзерге Париж Коммунасы урамы, 35) беренче катында яши һәм шунда 1902 елның 21 августында (3 сентябрендә) вафат була.

Әд.: Исламов Р. Каюм Насыйри һәм аны өйрәнү // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. 2017; Мозаффар М. Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Шура. 1913. № 6; Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Каюм Насыйриның мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Хатип Алишев истәлекләре // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Р.Ф.Исламов.

КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң ВАФАТЫ́, Каюм Насыйри белән хушлашу чарасы. К.Насыйри 1902 елның 21 августында (3 сентябрендә) 77 яшендә туганы Мөхәммәтбәдигъ *Хөсәенов* йортында вафат була. 5 нче Таш мәчетнең метрика дәфтәрендә аның үлеменең сәбәбе итеп картлык күрсәтелгән.

К.Насыйрины соңгы юлга озату чарасында кешеләр аз була. Бу вакыйганың шаһиты булган журналист В.*Бәхтияров* болай дип яза: «Мин Бәдигъ мөәзин өенә барып кергәндә, Каюм абзыйның гәүдәсе идәнгә, искерәк бер палас өстенә куелган иде. Мәет тирәсенә шул мәхәлләнең мулласы Йосыф ахун Сәгыйтов, Казанның бердәнбер яңалыкны сөйләүче, русча яхшы укый-яза белүче Бишбалтаның ахун Шәрәфетдин Абызов, Касыйм мулла Салихов. Бу күрсәтелгән муллалардан башка тагын берничә чалмалы садакачы картлар тезелешеп утырганнар иде». Аның истәлегеннән күренгәнчә, тәһлил укылганнан соң, К.Насыйриның җәсәден өйдән алып чыгып, мәчет янына алып баралар. Җеназа намазын Йосыф хәзрәт укый. Аннары мәрхүмнең гәүдәсен, Печән базары почмагында җыелышып эш көтеп торучылар күтәреп, шәһәрнең Яңа Татар бистәсе зиратына алып китәләр.

В.*Бәхтияров*, Казанның галимне соңгы юлга озатуда катнашмаган мөхтәрәм кешеләренең — танылган дин әһелләре, язучылар, морзалар, укытучыларның исемнәрен атап, үзенең тирән борчылуын белдерә. Язучы Г.*Рәхим* мәкаләсендә Касыйм хәзрәтнең түбәндәге сүзләрен китерә: «Җеназасында бары берничә генә кеше булып, бер-ике иң якын карендәшләреннән башка Казан халкыннан аны озатырга килүче булмаган. Җеназасында булучылардан Касыйм хәзрәт, Тукайны күмгән вакытта, 10 ел эчендә халыкның аңында үзенең олуг кешеләрен тәкъдир итүендә ни кадәр аерма булуына гаҗәпсенеп, бу сүзләрне миңа сөйләгән иде». Шулай ук кара: *Исхакый* Г., *Каюм Насыйриның кабере*.

Әд.: Бәхтияров В. Каюм абзый Насыйри турында кечек бер истәлек // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Каюм Насыйриның мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922.

Р.Ф.Исламов.

КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң КАБЕРЕ́, Каюм Насыйри Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында 1902 елның 21 августында (3 сентябрендә) җирләнә. Аның кабере Шиһабетдин Мәр-

җаниныкыннан ерак түгел урнашкан. Өстенә гади генә таш куелган, аңа Мөхәммәтбәдигъ *Хөсәенов* тарафыннан шундый язулар язылган:

«Һәза әл-мәркадү / Габделкаюм Габденнасыйр угылы / Белең йитмеш йитегә ирде гомере / Ничә китаб рисалә кылды тәсъниф / ихбә әйләде эшне тәсъвиб / ки мең тукыз йөз икенчедә мәкнүн / егерме бере август иде



К.Насыйриның кабере. Казан, Яңа Татар бистәсе.


мәдфүн / нур Аллаһу мәркадә. / (Бу — Габделкаюм / Габденнасыйр угылы кабере. / Белегез: җитмеш җидедә иде гомере, / Ничә китап, рисалә язды, / Эшне дөрес итеп эшләде. / Мең тугыз йөз икенчедә вафат булды, / Егерме беренче августта җирләнде. / Аллаһы аның каберен нурландырсын». / Соңыннан аның кабер өсте берничә тапкыр төзекләндерелә. Шулай ук кара: *Каюм Насыйриның вафаты*.

Әд.: Гайнетдинов А.М. Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйрига куелган кабер ташы, 1902 ел // Гайнетдинов А.М. Казанның Яңа Татар бистәсе зираты эпиграфик истәлекләре. Казан, 2023; Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Каюм Насыйриның мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Насыри (Насыйри) Каюм (Габделькаюм) Габдельнасырович // Ново-Татарское кладбище Казани. Каталог-справочник памятных захоронений. Казань, 2021.

Р.Ф.Исламов.

КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң КУЛЪЯЗМАЛАРЫ́, Каюм Насыйриның кулъязма мирасы. Үзе исән чагында ук күп кенә хезмәтләрен һәм аларның кулъязмаларын, яшәгән өе 1885 елда янганнан соң, Казан университеты профессоры И.Ф.Готвальдка сакларга тапшыра, шулай ук башка кешеләргә дә күчереп язарга бирә. Галим үзе төзегән исемлектәге күпчелек хезмәтләренең кулъязмалары төрле сәбәпләр аркасында юкка чыккан булу ихтимал.

К.Насыйриның кулъязма мирасында бастыру өчен китап рәвешендә әзерләнгәннәре («Кырык вәзир», «Ләһҗәи татари»ның беренче томы, «Җәгърәфияи кәбир»нең беренче кисәге, «Истыйлахате җәгърәфия», «Мәҗмәгыль әхбар», «Лөгате рус», «Нәмүнәи яки әнмүзәҗ», «Мәнафигы әгъза», «Җәваһир әл-хикәят», «Гыйльме һәндәсә», «Хисаплык», «Тарихы әнбия», «Санаигы голфания», «Мифтахел фөркан» һ.б.), үзе төпләп, «Күрелгән һәм



Могу выдержать экзамены.
1 по русскому языку,
2 по русской грамматике,
3 по Арифметике,
4 по Географии российской им и
5 по русской истории


1 По Арабскому,
2 по персидскому,
3 по турецкому,
4 по джагатайскому и
5 по татарскому языкам.

ишетелгән хәбәрләр язылыр» дип исемләнгән ике дәфтәре (газеталардан өземтәләр, әһәмиятле даталар, ишеткән төрле сүзләр, фольклор материаллары, шигырь үрнәкләре, хикәяләр, борынгы үлчәүләр һ.б.), уку-укыту эшенә караган язмалары (планнар, укыту эшенә караган законнар, хисаплар, циркулярлар һ.б.), төрле елларда нәшер ителгән календарьлары өчен әзерләнеп тә, басылмый калган материаллары, килешү документлары, васыять-намәләре, төрле телдәге китапларның күчермәләре, тәрҗемәләре, төрле характердагы башка язмалары сакланган.

Кулъязмалар хәлендә сакланып калган әлеге материалларның күпчелеге хәзерге вакытта — Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге* Шәрекъ бүлекчәсендә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының *Язма мирас үзәгендә*, *Татарстан Республикасы Дәүләт архивында*. *Татарстан Республикасы Милли музеенда* сакланган Казан тарихы турындагы кулъязмаларында шәһәрнең архитектура һәйкәлләренә, урамнарга кыскача характеристика бирелә, Сембер губернасы Буа өязенең икътисади-географик тасвирламасы китерелә.

К.Насыйриның кулъязмалары турында беренче мәртәбә язучы, әдәбият галиме Мөхәммәт *Гали* «Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр» (1945) дип аталган китапта язып чыга һәм мәгърифәтченең кайбер шигырьләрен, «Игъланнамә»сен урнаштыра. Аның тууына 120 ел тулуга багышланган җыентыкта (1948) исә бу мәсьәләгә киңрәк туктала. Шулай ук кара: *Каюм Насыйриның хатлары*.





Әд.: Гали М. Каюм Насыйриның кулъязма мирасы // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; шул ук. Каюм Насыйриның кулъязмалары // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; Каюм Насыйриның басылмаган кулъязмасы // Совет әдәбияты. 1950. № 2; Ногман Мостафа. Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. II чыгарылыш. — Каюм Насыйри кулъязмалары. Казан, 1958; Багаутдинова Д.Б. Фонд Каюма Насыри в Государственном музее ТАССР // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Р.Ф.Исламов.

«КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң МӘҖМУГАСЫ́», Каюм Насыйри турында мәкаләләр җыентыгы. Ул мәгърифәтче әдипнең вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте белән Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршындагы *Гыйльми үзәк* тарафыннан 1922 елда бастырыла.

Мәҗмуганы төзүнең төп сәбәбе түбәндәгечә аңлатыла: «Татар халкының әдәби-мәдәни хәрәкәтләре тарихында зур бер дәвернең беренче — башлангыч, хәзерлек — баскычында бөек хезмәтләр кылып үткән Каюм Насыйри хакында буңарчы матбугатымызда (таркау гәзит, журнал мәкаләләреннән башка) кулга тотарлык һичбер нәрсә юк иде. Хәлбуки, тарихи эшләрне аңлау өчен дә, Каюм бабаның һәм аның замандашларының тормышлары, зәминнәре [урыннары], эшләре белән танышу өчен дә, һич булмаса, иң төп мәгълүматны бергә туплаган бундый бер хезмәткә-әсәргә бик зур ихтыяҗ һәркемгә мәгълүм иде». Шулай



«Каюм Насыйриның мәҗмугасы». Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. ТССҖ дәүләт нәшр., 1922.

ук вакытның аз булуы сәбәпле, бу китапка барлык «хатирәләр, хатлар, аерым кешеләрнең карашлары кебек тәфсилләр җыелып бетә алмаганы, башкача да кайбер ачыклыклар калганы» хәбәр ителә, К.Насыйриның йөз еллык юбилеена эшләнер дигән өмет белдерелә.

Мәҗмугада Галимҗан *Ибраһимовның* «Мәҗмуганы чыгаручы һәйәттән», «Каюм Насыйриларның тарихи урын-

нары», «Яңа әдәби татар теленең беренче баскычлары», Гали *Рәхимнең* «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле», Әхәт Гаффарның «Рус матбугатында Каюм Насыйри», Газиз *Гобәйдуллинның* «Каюм Насыйриның гыйльми-тәгълими хезмәтләре», «Насыйри чын гыйльми-фән бабында», Хуҗа *Бәдигыйның* «Каюм Насыйриның халык әдәбиятын җыю һәм тикшерү юлында хезмәтләре», Җамал *Вәлидинең* «Каюм Насыйрида татар теле» дигән мәкаләләре һәм Каюм Насыйриның «Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары (Борынгы шаманизм калдыклары)» исемле хезмәте рус телендәге басмасыннан тәрҗемә ителеп бирелгән.

Чыг.: Каюм Насыйриның мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922.

Әд.: Исламов Р. Каюм Насыйри һәм аны өйрәнү // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017.

Р.Ф.Исламов.

«КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң МОҢАРЧЫ́ БАСЫЛМАГА́Н ӘСӘРЛӘРЕ́. МӘҖМУГА́», Каюм Насыйри турында мәкаләләр һәм аның кайбер әсәрләре җыентыгы. Әдипнең тууына 100 ел тулу уңае белән Татарстан Мәгариф халык комиссариатының төбәкне өйрәнү бюросы тарафыннан 1926 елда нәшер ителә. Аның төзүчесе — Галимҗан *Ибраһимов*, мөхәррире итеп Гали *Рәхим* билгеләнә.

Мәҗмуганың кереш өлешендә басмага әзерләү сәбәпләре турында: «Йөз еллык бәйрәм уңае белән Каюм баба турында тикшерү башлангач, безгә берьюлы ике җирдән чишмә ачылды: 1) Газиз Гобәйдуллин иптәш Казан университетының көтепханәсеннән Насыйриның шул Готвольдка бирелгән, моңарчы басылмаган кулъязма әсәрләрен эзләп алып Гыйльми үзәккә тапшырды. Бу, әлбәттә, бик зур байлык булды; 2) Зөя өязендәге укытучы иптәшләрдән Каюм Насыйри турында һәм аның үз әйберләреннән бик күп кадерле нәрсәләр китереп тапшырдылар. Болар арасында музей әйберләре белән бергә мәрхүмнең кайбер гыйльми документлары, китаплары, язмалары да бар иде», — диелә.



Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Казан, 1926.

Җыентыкта Г.Ибраһимовның «Башлангыч», «Каюм бабаның йөз еллыгы», Газиз *Гобәйдуллинның* «Насыйри кулъязмаларының гыйльми кыйммәтләре турында», Г.Рәхимнең «Башлангыч», Мөхетдин *Корбангалиевнең* «Каюм Насыйри турында истәлекләр», Гыйлемдар *Баембитовның* «Каюм Насыйрига 100 ел тулу белән», Фатих *Әмирханның* «Бу рухта беренче...», Гариф Латыйфның «Насыйри турында истә калганнар» исемле мәкаләләре, Каюм Насыйриның 1880 елларда язылган «Казан тарихы турында (Халык сөйләве буенча)», «Аксак Каратун, Пугачев һәм Ишбулат мулла хакында риваятьләр», «Археология материалла-

ры (Зөя өязе авыллары буенча)», «Татар этнографиясе материаллары» дигән хезмәтләре, мәгърифәтчене искә алу чаралары турында көндәлек матбугатта басылган материаллар урнаштырылган. Анда беренче тапкыр К.Насыйриның туган елына төгәллек кертелә: элекке хезмәтләрдә ул 1824 ел дип күрсәтелгән була.

Чыг.: Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926.

Әд.: Исламов Р. Каюм Насыйри һәм аны өйрәнү // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017.

Р.Ф.Исламов.

КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң ПА́СПОРТЫ, Россия гражданының шәхесен таныклаучы рәсми документ. 1898 елның 22 июнендә Казан губернасы Зөя өязе старшинасы тарафыннан Каюм Насыйригa шәһадәтләнеп бирелгән паспортның соңгысы була. Аның гамәлдә булу чоры — 5 ел. Паспорт рус телендә язылган 5 биттән тора. Төп нөсхәсе ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының *Язма мирас үзәгендә* саклана.

Эчтәлеге: Паспорт кенәгәсе. / № 1197. / Биш елга. / Казан губернасы Зөя өязе Шырдан волосте старшинасы тарафыннан мең сигез йөз туксан сигезенче елның июнь ае 22 көнендә Казан губернасы Зөя өязе Шырдан волосте Кече Шырдан авылы крестьяны Габделкаюм Габденнасыйровка бирелде. / Кенәгәнең иясе: Габделкаюм Габденнасыйров. / 1. Дәрәҗәсе: Крестьян. / 2. Туган вакыты — / 3. Яки яше: 69 яшь. / 4. Дине: Мөхәммәди дине. / 5. Даими яшәү урыны: Кече Шырдан авылы. / 6. Никахлымы яки никахта торганмы: Никахлы булган.



Каюм Насыйриның паспорты.

Чыг.: Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык, 2017.

И.Х.Хәлиуллин.

КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң ТОРМЫШЫ́ ҺӘМ ИҖАТЫ́ ХАКЫНДА́ БИБЛИОГРА́ФИЯ, библиографик белешмә. 1945 елда әдәбият галиме М.*Гайнуллинның* «Каюм Насыйри (Аның фәнни һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге)» хезмәтендә рус телендә нәшер ителә. Библиографик күрсәткеч Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышлап уздырылган гыйльми сессия материаллары җыентыгында «Библиографик белешмәләр»дә (төзүчесе — М.Гайнуллин) урнаштырыла. Ул «Каюм Насыйриның басылып чыккан әсәрләре» һәм «Каюм Насыйри турында рус һәм татар матбугаты» дигән ике өлештән тора. Соңрак белешмәнең тулыландырылган варианты аерым китапчык итеп бастырылып (1952), К.Насыйриның 1953 һәм 1956 елларда дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»ендә бирелә. К.Насыйриның тууына 150 ел тулу уңаеннан 1975 елның 14 нче февралендә үткәрелгән конференция материаллары тупланмасында юбилей чаралары мөнәсәбәте белән матбугатта басылып чыккан мәкаләләрнең исемлеге китерелә. Мәгърифәтченең Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соң нәшер ителгән басмалары, вакытлы матбугат һәм аерым җыентыкларга кергән әсәрләре һәм хезмәтләре, аның турындагы әдәбият исемлеге 1975 елда дөнья күргән ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең икенче томында урнаштырыла. Галим хакындагы берникадәр библиографик белешмә Г.Г.*Батыршинаның* «Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге» дип аталган монографик хезмәтенә дә керә.

Мәгърифәтченең тулыландырылган библиографик күрсәткече 2017 елда «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык»та бастырыла. Аның хронологик кысалары 1860–2017 елларны колачлый. Анда К.Насыйриның әсәрләреннән тыш татар, рус, башкорт, казакъ, мари, таҗик, төрек, төрекмән, үзбәк, француз телләрендә аның тәрҗәмәи хәле һәм күпкырлы эшчәнлеге турында китаплар, мәкаләләр, диссертацияләр һәм авторефератлар бар.

К.Насыйриның тууына 200 ел тулуга әзерлек уңаеннан Р.Ф.Исламов тарафыннан 2024 елда тулыландырылган биобиблиографик күрсәткеч аерым китап булып басыла.

Чыг.: Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953; шул ук. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956; шул ук. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1975. 2 т.


Әд.: Батыршина Г.Г. Каюм Насыйриның лексикографик эшчәнлеге. Казан, 2007; Исламов Р.Ф. Каюм Насыйри: Биобиблиографик күрсәткеч. Казан, 2024; Татар халкының атаклы галиме, мәгърифәтчесе һәм язучысы Каюм Насыйри (1825–1902): әдәбият исемлеге. Казан, 1952; Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан, 1948; Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Гайнуллин М. Каюм Насыри (Его научная и просветительская деятельность). К 120-летию со дня рождения. Казань, 1945.

Р.Ф.Исламов.


КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң ХАТЛАРЫ́, шәхси хатлар. Каюм Насыйриның 1845 елдан башлап әти-әнисенә, якын туганнарына, шул чорның күренекле галимнәренә һәм замандашларына язган хатларының күп кенә төп нөсхәләре сакланып калган. Бүгенге

көндә К.Насыйриның берничә йөз хаты булуы мәгълүм. Аларның күпчелек өлеше эти-әнисенә һәм туганнарына юллана. Хатларның күпчелеге хәзерге вакытта Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге* Шәрекъ бүлекчәсендә, ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының *Язма мирас үзәгендә* саклана.

Хатларның эчтәлеген, нигездә, хәл-әхвәл белешү, көнкүреш мәсьәләләре, Казанда яшәүче туган-тумачаларының хәлләре һәм башка хәбәрләр тәшкил итә. Абзасы Габделхәйгә күндергән хатларда (алар иң күбесе) сүз сәүдә мәсьәләләре, аның йомышларын үтәү, аңардан килгән кайбер товарларны хәл итү турында барса да, үзен кызыксындырган китапларны алдыруга да игътибар бирелә. Башка кешеләргә язган хатларында үзенең китапларын почта аркылы җибәрүе, биреп торган китапларын соравы турында мәгълүматлар бар. Мәсәлән, Салих исемле кешегә (1893 ел, 18 июль): «Бер данә «Лөгате рус», бер данә «Зирагать», бер данә «Кавагыйде китабәт», бер данә «Иршад әт-этбиха», бер данә «Җәгърәфия» йибәрдем һәм Галиевтәге акчаңызны алдым», — дип яза. Көнчыгыш телләре укытучысы Я.И.Фортунатовка татар телендә язган хаты түбәндәгедән гыйбарәт: «Яков Иванович! Минем «Мәҗмәгыль әхбар» китабын биреп җибәрегез. Тагын минем Бикчурин китабы сездә түгел микән? Бу китап та кирәк булды. Янә словарьның әүвәлге беловой текстлары



Каюм Насыйриның абзасы Габделхәйгә язган хатының беренче бите. 1865 ел, 9 май.



Каюм Насыйриның энесе Габделкавига язган хаты. 1887 ел, 8 июнь.

Сездә калган булса кирәк... Габделкаюм». Писарев фамилияле студентка рус телендә болай мөрәҗәгать итә: «Прошу Вас возвратить мне мою «Татарскую грамматику» Насырова, которую Вы взяли у меня давно, я Вашу квартиру не найду. К. Насыров».

Аларны беренче булып матбугатта Шәйхулла *Алкин* игълан итә. Мәгърифәтченең эти-әнисенә язган ике хатының бер авылдагы өйнең чормасыннан үзе табып алган нөсхәләрен «Аң» журналында (1912) бастыра. Мөхәммәт *Гали* галимнең Казан университеты китапханәсендә сакланган кайбер хатларын К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары җыентыгында (1948), баш библиограф Д.Г.Абдуллина, кириллицага күчереп, «Насыйри К. Сайланма әсәрләр» дүрт томлыгының өченче томында (2005) бастырып чыгаралар. Бу китапханәдәге һәм Язма мирас үзәгендәге хатларның күп өлеше филология фәннәре докторы Р.Ф.*Исламов* әзерләп бастырган «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык»та (2017) гамәлдәге татар графикасында урнаштырыла.

К.Насыйриның хатлары аның тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнүдә өстәмә материал булып тора, шул чордагы вазгыятьне тулырак күзалларга, аерым шәхесләр турында тулырак мәгълүмат тупларга ярдәм итә.

Әд.: Алкин Ш. Каюм Насыйри хатлары // Аң. 1912. № 1; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2005. 3 т.

Р.Ф.Исламов.

КАЮ́М НАСЫЙРИНЫ́Ң ЮБИЛЕЙЛАРЫ́, Каюм Насыйрины искә алу чаралары. Элек-электән әдип-галимнең төрле юбилейларын үткәрү әзлекле һәм дәвамлы башкарылып килә.

Шундый чараларның беренчесе Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәк карары белән К.Насыйриның вафатына 20 ел тулу уңаеннан 1922 елның сентябрендә искә алу көне буларак билгеләп үтелә. К.Насыйрины белгән кешеләргә кулларында булган материаллар, язулар, хатирәләр, китаплар, рәсемнәр һәм башка әйберләр белән ярдәм итүләрен үтенеп мөрәҗәгать ителә һәм әлемтә өчен адрес күрсәтелә. Нәтиҗәдә, мәҗмуга төзелеп, шул ук елда нәшер ителә.

Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәкнең татар редакциясе коллегиясе тарафыннан 1925 елның 10 феврале утырышында, Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулуны билгеләп үтү мәсьәләсе тикшерелеп, төрле карарлар кабул ителә, шулар арасында түбәндәгеләр дә көн кадагына куела: «Йөз ел тулган көнне К.Насыйриның шәхесе белән киң катлауны таныштыру, аның ролен ачыклау һәм хезмәтләрен җентекләү максатында зур ачык җыелыш уздыру»; «4 Евангелистлар урамын К.Насыйри исеменә алыштырырга». К.Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан матбугатта аның тәрҗемәи хәленә карата кызыклы мәгълүмат бирелә. Аерым алганда, аның 1824 елда түгел, ә 1825 елда туганлыгын дәлилли торган чыганакларның табылуы хакында языла (тулырак кара: *Гыйльми үзәк*).

Бөек Ватан сугышы барган 1945 елның мартында К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган юбилей чаралары зур масштабта үткәрелә. Казанда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында 18–19 мартта, Мәскәүдә 26 мартта гыйльми сессияләр уздырыла. Анда академик С.П.Обнорский, әдәбиятчылар М.*Гай-*

нуллин, М.*Гали*, Ж.*Вәзиева*, тел галимнәре Н.К.*Дмитриев*, Ш.Р*амазанов*, В.*Хангилдин*, Л.Ж.Җәләлетдинов (Л.Ж.*Җәләй*), М.Э.Фазлуллин, Р.А.Хәкимова, тарихчылар Н.И.*Воробьёв*, Х.Г.*Гыймади*, фольклорчы Х.*Ярми,* педагоглар В.М.*Горохов,* М.К.Бакиев, табиб Ф.*Мөхәммәдъяров* галимнең тормышы һәм эшчәнлеге киң яктыртылган докладлар белән чыгыш ясыйлар. Бу материаллар татар һәм рус телләрендә аерым җыентыклар рәвешендә нәшер ителә. Анда К.Насыйриның авылдашлары Гыйбадулла *Төхфәтуллин*, Талип *Гайсин*, Гыйльман *Ногманов*, Мәсхәпҗамал *Ибәтуллина*, Гатаулла *Дусаев*, әнисе ягыннан туганы Габделбарый Насыйров, дин эшлеклеләре Зыя *Бәхтияров*, Хатыйп *Алишевның* галим турында кызыклы истәлекләре дә урын ала. Татар фронт газеталарының берсендә әлеге юбилей уңаеннан язылган махсус мәкалә басылып чыга (шулай ук кара: *Истәлекләр*).

Галимнең 125 еллыгы да матбугатта мәкаләләр белән билгеләп үтелә. Әдәбиятчы М.Гали Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә К.Насыйриның аңарчы мәгълүм булмаган «Хитабате лиәһли Казан» («Казан халкына мөрәҗәгать») дип аталган 150 бит күләмендәге кулъязма хезмәтен табып ала һәм укучыларны аның аерым үрнәкләре белән таныштыра. «Бу әсәр, — диелә кереш өлештә, — ул вакыттагы Казан татарларының тормыш-көнкүрешләренә, гадәт-йолаларына һәм тәрбия мәсьәләренә карата К.Насыйриның үзенчәлекле тәнкыйть карашларын бик ачык чагылдыра».

1975 елда К.Насыйриның тууына 150 ел тулуга багышланган юбилей чарасы тантаналы рәвештә зурлап үткәрелә. Шул елның 11–12 февралендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан университеты һәм Казан педагогия институты белән берлектә Татарстан җитәкчелеге, галимнәр, киң җәмәгатьчелек катнашында университетның Актлар залында фәнни конференция уздырыла. К.Насыйри яшәгән чорны, аның фәлсәфи карашларын, татар әдәбиятын һәм телен үстерүгә керткән өлешен, тарих, археология, этнография, фольклор өлкәсендәге фәнни казанышларын, педагогик эшчәнлеген, ТАССР Дәүләт музеенда саклана торган фондын яктырткан 26 доклад тыңлана. Әдәбият галиме С.Х.*Акбиевнең* К.Насыйриның кумык мәгърифәтчесе Әбусуфьян *Акаевның* иҗтимагый-педагогик эшчәнлегенә бәрәкәтле тәэсире турындагы чыгышы аеруча зур кызыксыну уята. Конференция материаллары аерым җыентык итеп чыгарыла (тулырак кара: «*Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри*»). 13 февральдә Татар дәүләт академия театры бинасында тантаналы җыелыш була, сәнгать осталары зур концерт программасы белән чыгыш ясый. Икенче көнне К.Насыйриның туган ягында — Олы Ачасыр авылы Мәдәният йортында шулай ук фәнни конференция уздырыла, Яшел Үзән шәһәренең сәнгать коллективы концерт куя.

К.Насыйриның тууына 170 ел тулу уңаеннан Казан педагогия институтында «Каюм Насыйри һәм хәзерге педагогика» дигән темага укулар уздырыла.

2011 елның 2 февралендә ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, төрле фәнни институтлар, югары уку йортлары галимнәре, язучылар, музей хезмәткәрләре катнашында Казанда *Каюм Насыйри музеенда* «Каюм Насыйри мирасын саклау һәм аны киләчәк буыннарга тапшыру проблемалары», 2013 елның 6 февралендә

шунда ук «Каюм Насыйри мирасы хәзерге вакыттагы белем бирү процессында һәм музей киңлегендә» дигән түгәрәк өстәлләр үткәрелә.

К.Насыйриның тууына 190 ел, казакъ мәгърифәтчесе, шагыйрь Абай Конанбаевның тууына 170 ел тулу уңаеннан 2015 елның 26–27 февралендә Казакъстан Республикасы башкаласы Астанада һәм Казанда Халыкара «Төрки дөнья мәгърифәтчеләренең иҗади мирасы» фәнни-гамәли конференциясе булып уза. Аның материаллары рус, татар һәм казакъ телләрендә нәшер ителә. К.Насыйри юбилеена багышлап, ТР Фәннәр академиясенең Тарих институты тарафыннан «Урта һәм югары белем бирү системасында татар телендә укыту: тарих, хәзерге заман һәм перспектива» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе уздырыла.

2022 елның 24–25 февралендә Казанның Каюм Насыйри исемендәге 80 нче гомуми урта белем бирү мәктәбендә төбәкара, 2023 елның 16–17 февралендә — II, 2024 елның 27–28 февралендә — III «Насыйри укулары» — «Насыровские чтения» халыкара фәнни-гамәли конференцияләре; 2022 елның 4 мартында ТРның Яшел Үзән шәһәрендә Каюм Насыйри исемендәге XX халыкара яшьләр фәнни-гамәли конференциясе үткәрелә.

2023 елның 13 февралендә М.Акмулла исемендәге Башкорт педагогия университеты Казан федераль университеты Каюм Насыйри институтының Уфа мәдәни белем бирү үзәге белән берлектә «Каюм Насыйри: шәхес, галим, остаз» коворкингы уздыра.

2024 елның 14 февралендә Казанда Каюм Насыйри музеенда ТР Мәдәният министрлыгы, ТР Милли музее җитәкчелеге вәкилләре, галимнәр, дин әһелләре һәм киң җәмәгатьчелек катнашында «Каюм Насыйри: мирасын музей киңлегендә актуальләштерү» темасына, шул ук елның 25 апрелендә ТР Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының Энциклопедистика үзәге тарафыннан киң җәмәгатьчелек катнашында «Каюм Насыйри» персональ энциклопедиясенең текст һәм иллюстрацияләр контентлары икърар ителешенең фәнни-методик үзенчәлекләре» темасына түгәрәк өстәлләр оештырыла. Фәнни-мәдәни чаралар шулай ук К.Насыйриның туган авылында, республиканың башка төбәкләрендә даими рәвештә уздырыла.

Чыг.: Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926; Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Насыйри укулары — Насыровские чтения: сб. материалов I Межрег. науч.-практ. конф. с междунар. участием. Казань, 2022; Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвященных 120-летию со дня рождения). Казань, 1948; Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы: материалы Рег. науч.-практ. конф., посвящ. 190-летию со дня рожд. К.Насыри. Казань, 2015; Творческое наследие просветителей тюркского мира: материалы Междунар. науч.-практ. конф., посвящ. 190-летию со дня рожд. К.Насыри и 170-летию со дня рожд. А.Кунанбаева (гг. Казань-Астана) = Төрки дөнья мәгърифәтчеләренең иҗади мирасы: К.Насыйриның тууына 190 һәм А.Кунанбаевның тууына 170 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конф. материаллары (Астана-Казан, 2015 ел, 26–27 февраль). Казан, 2015 = Түік әлемі ағартушыларының шығармашылық мұрасы: К.Насыридің 190-жылдығы мен

Абайдың 170-жылдығына арналған Халыкаралық ғылыми-практ. конф. материалдары (Астана-Казан қк., 26–27 акпан 2015 ж.). Қазан, 2015; XX Междунар. молодежная науч.-практ. конф. им. Каюма Насыри. Казань, 2022; Сборник материалов II Междунар. науч.-практ. конф. «Насыйри укулары» — «Насыровские чтения». Казань, 2023.

Әд.: Гайнуллин М. Бөек мәгърифәтче һәм патриот // Совет әдәбияты. 1950. № 2; Гыйльми Үзәктә // Безнең юл. 1925. № 5; К.Насыйрига багышлап // Казан утлары. 1995. № 4; Каюм Насыйрины искә төшерү // Татарстан. 1922. 19 июнь; Каюм Насыйриның туганына йөз ел тула // Кызыл Татарстан. 1925. 8 февраль; Каюм Насыйриның тууына 120 ел // Ватан намусы өчен. 1945. 11 апрель; Каюм Насыйриның тууына йөз ел тулу уңае белән зур җыелыш! // Кызыл Татарстан. 1925. 15 февраль; Латыйф Г. Каюм Насыйрины искә төшерү турында зур җыелыш // Кызыл Татарстан. 1925. 18 февраль.

Р.Ф.Исламов.

КӘРИ́МОВЛАР БАСМАХАНӘСЕ́, ТАШБАСМАСЫ́ ҺӘМ ХӘРЕ́Ф КОЮ́ ШИРКӘТЕ́. Казандагы беренче шәхси татар басмаханәсе. Хуҗалары — китап белән сәүдә итүчеләр, наширләр бертуган Шәрифҗан, Мөхәммәтҗан һәм Хәсән Кәримовлар. 1899 елда Кәримовларның китап сату фирмасы эшчәнлеге кысаларында М. һәм Ш.Кәримовлар тарафыннан нигезләнә. 1900 елдан хәреф кою ширкәте эшли. 1901 елда ташбасма да ачыла һәм басмаханә «Кәримия матбагасы» дип аталып йөртелә башлый. Башта — 11 кеше, 1902 елда 32 кеше эшли.



Кәримовларның китап сату фирмасы. Бертуган Кәримовларның нәшрият-сәүдә комплексы бинасы. Арх. П.И.Романов. 1883.

Беренче басмалары — «Мәҗмәгел ләтаиф» («Мәзәкләр җыентыгы», 1900), Г.Камалның «Бәхетсез егет» (1900) пьесасы һ.б. 20 йөз башында Казанда татар телендә чыккан китапларның яртысы Кәримовлар басмаханәсендә нәшер ителә. 1900 елның 10 аенда татар телендә 433,1 мең данә тираж белән 36 исемдә китап басыла. Алга таба ел саен якынча 1,5 млн данә тираж белән якынча 130 исемдә, 1901–1917 елларда 20 млн нан артык тираж белән 1763 исемдә китап чыгарыла. Алар арасында урта гасырлар авторлары әсәрләре, татар җәдит мәктәпләре өчен дәреслек-әлифбалар, үзөйрәткечләр, грамматика буенча ярдәмлекләр, арифметика, география дәреслекләре, ислам тәгълиматына һәм йола, гореф-гадәтләренә, Коръән уку кагыйдәләренә багышланган китаплар, Коръән (17 басма), догалыклар һ.б. бар. Басмаханәдә шулай ук татар халык җырлары, әкиятләре, табышмаклары җыентыклары нәшер ителә. 1902 елда Каюм Насыйриның башта 1898 елда *Перов И.С. ташбасмаханәсендә* чыгарылган «*Кырык бакча*» әсәре басыла.

Әд.: Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. Казань, 1974; Мифтахов З.З. Развитие полиграфической базы в Татарии (октябрь 1917–1927 гг.) // Здравствуй, книга! Казань, 1989.

И.Х.Хәлиуллин.

КӘРИМУ́ЛЛИН Әбрар Гыйбадулла улы (29.05.1925, Татарстанның Мамадыш кантоны (хәзер Саба районы) Чәбия-Чүрчи авылы – 19.09.2000, Ка-

зан), филолог, китап белеме галиме, библиограф, публицист, филология фәннәре докторы (1978), ТР Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы (1992), ТССРның атказанган фән эшлеклесе (1990), ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1991). Бөек Ватан сугышында катнаша.

Казан университетын тәмамлый (1953). 1941 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, башта — колхозчы, аннары — Нырты хастаханәсендә хисапчы, башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли. 1943 елдан — Кызыл Армия сафларында, 1947 елда демобилизацияләнә. 1953–1964 елларда — Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә, 1964–1992 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында. 1991–2000 елларда ТР Милли китапханәсендә баш фәнни хезмәткәр булып эшли.

Хезмәтләре татар басма китабының барлыкка килү һәм үсү тарихын өйрәнүгә, филология һәм библиографиягә карый. Каюм Насыйриның наширлек эшчәнлегенә һәм «Таң йолдызы» проектына багышланган мәкаләләрендә галимнең мәгърифәтчелек өлкәсендә татар телендә газета чыгару юнәлешенә дә аерым игътибар һәм зур әһәмият бирүе, шул эш белән янып йөрүе, 1862 елда үзе һәм ташбасмаханә хуҗасы мещан Мөхәммәтвәли Яхин исеменнән Казан хәрби губернаторы П.Ф.Козляниновка әлеге ният белән мөрәҗәгате, алар үтенеченең кире кагылу сәбәпләре, проектның гамәлгә ашмавында Н.И.Ильминскийның да катнашы булуы яктыртыла; «Таң йолдызы» проекты татарларда һәм, гомумән, Россия империясенең төрки халыклары арасында туган телләрендә *вакытлы матбугат* оештыру омтылышының тәүге чагылышы буларак сыйфатлана.



Ә.Г.Кәримуллин

К.Насыйри нәшер иткән календарьларга аналитик күзәтү ясап, Ә.Г.Кәримуллин: «Ничек кенә булмасын, татар журналистикасының тәүге адымнары Каюм Насыйри эшчәнлегеннән башлана дип раслый алабыз. Аның календарьларының эчтәлеге, тематикасы, анда басылган материалларның язылу формасы, теле шул турыда сөйли», — дип яза. Тарих фәннәре кандидаты Л.Ж.Миңнуллина сүзләре дә шуны раслый: «Каюм Насыйриның календарьлары татарча китап бастыру тарихының яңа сәхифәләрен ача, аларда шул чор кешеләренең тулы тормыш алып баруларын өчен барлык, тарихи материллардан башлап төрле көнкүреш әйберләре әзерләүгә кадәр мәгълүмат бар. Бу Каюм Насыйри календарьларын белешмәләр басмасы итеп характерлый».

1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар тел белеме библиографиясе (1786–1956). Казан, 1958; Татар матур әдәбияты библиографиясе (1917–1966). Казан, 1964; Каюм Насыйриның «Таң йолдызы» проекты // Казан утлары. 1975. № 2; Каюм Насыйри календарьлары // Әйдә халыкка хезмәткә: Күренекле татар публицистлары. Казан, 1985; Татарлар: Исемебез һәм җисемебез. Казан, 1991; Издательская деятельность Каюма Насыри и проект газеты «Таң йолдызы» // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Из истории печатного слова. Казань, 1984. Книги и люди: Исследование. Казань, 1985; Становление и развитие татарской советской книги. 1917–1932. Казань, 1989.

Әд.: Академия наук Татарстана. Казань, 1994; Абрар Гибадуллович Каримуллин: Биобиблиографический указатель. Уфа-Казань, 1995.

И.Х.Хәлиуллин.

әл-КӘЧИМИРИ́ Габдулла бине Таҗетдин (?–?), публицист, Каюм Насыйри турында истәлек язучы. Аның хатирәсе беренче мәртәбә «Шура» журналында (1913) дөнья күрә. Аннан соң әдәбиятчы Фатыйма *Ибраһимова* тарафыннан «Әдәби мирас»ның 3 нче китабында (1996) бастырыла.

Үзенең истәлегендә 1876–1877 елларда К.Насыйрида 4–5 шәкерт белән бергә русча укуы турында яза. Мәгърифәтченең төс-кыяфәтен, тормыш-көнкүрешен тасвирлый. Китапларының шәкертләр тарафыннан яратып укылуын искәртә. Автор үзе аның китапларын, бигрәк тә тыйб китапларындагы гарәпчә язылган дәва исемнәрен соравын, ул китапларны К.Насыйридан алуын хәбәр итә. Истәлегендә түбәндәге юллар китерелә: «...1899 ел июньдә Казанга баргач, Бәдигъ мөәзин [*Хөсәенов* Мөхәммәтбәдигъ] фатирына барып, янына кердем. Чәй эчеп утыра иде. Зуррак, төпләнгән бер китабын кулыма алып карадым. Ул исә «Ысуле җәгърәфияи кәбир» — «Азия кыйтгасы», «Африка кыйтгасы», «Җәзирәт әл-гареб» иде. Өчесен бергә бик матур итеп клеенка илә үзе тышлаган иде. «Бу ни хак?» — дип сорадым. «Ике сум», — диде. Мин: «Бер сум иллегә бирергә булмасмы?» — дип әйтүемә каршы: «Ул хакка бергәнче себерке итеп чабынырым», — диде. Күрәсең, минем бирүемдә сумасы да табылмаган булырга кирәк, чөнки күп бастыра алмый иде. Аз булгач, кыйммәт төшәдер. Ул заманда укучылар да аз иде. Халкымызның укымаганыннан зарланганын күп ишеттем. Китаплар күп бастырса да, сума җыя алмаган булырга кирәк...» Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Әл-Кәчимири Габдулла бине Таҗетдин. Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. 1913. № 10.

Ф.С.Гыйниятуллина.

КЕ́МПЕР Михаэль (08.11.1966), немец тарихчысы, ислам гыйлеме галиме, тарих фәннәре докторы, профессор.

Рур университетында (Бохум шәһәре, Германия) белем ала, анда ислам гыйлемен, славян һәм көнчыгыш телләрен өйрәнә. 1998 елга кадәр Изге Лаврентий университетының (Кантон шәһәре, Нью-Йорк штаты) Үзәк Евразия тарихы профессоры ассистенты. 1998 елдан Амстердам университетының гуманитар факультетында (Нидерландия), профессор, Көнчыгыш Европа тарихы һәм Көнчыгыш Европа тикшеренүләре кафедрасы мөдире; Амстердам төбәк, транснациональ һәм Европа тикшеренүләре мәктәбе директоры.

Хезмәтләре Россиядәге, Үзәк Азиядәге һәм Кавказдагы исламга, шулай ук Европада көнчыгышны өйрәнү тарихына карый. «Татарстанда һәм Башкортстанда суфилар һәм галимнәр (1789–1889): рус хакимлеге астында ислам дискурсы» (2008) китабы, «Совет көнчыгышны өйрәнү традициясе» (2011) коллектив монографиясе һәм башка хезмәтләр авторы.

Кемперның «Татарстанда һәм Башкортстанда суфилар һәм галимнәр» хезмәтендә 18–19 йөзләр ахырында татар һәм башкортлар арасында суфичылыкның әлегә кадәр өйрәнелмәгән мәсьәләләре карала һәм татар галимнәренең дини һәм дөньяви хезмәтләре фәнни яктан анализлана. Анда автор киң фактик материал ярдәмендә бу катлаулы күренешнең үзенчәлеген күрсәтә. Фәнни тикшеренүендә

мөселман мәгарифе һәм аның учреждениеләре тирәлегеннән чыгып киткән һәм аның урынына күбрәк рус даирәләрендә, ягъни традицион ислам дискурсыннан читтә торучы һәм ислам дискурсы белән көндәшлек итүче Европа дискурсында катнашкан мөселман-татар зыялылары вәкилләренә аерым игътибар бирелә. М.Кемпер алар арасыннан, «секуляр» татар фәненең үзәк фигурасы буларак, 1855–1870 елларда Казан өяз руханилар училищесында, Казан руханилар семинариясендә татар теле укытучысы булып эшләгән галим-мәгърифәтче Каюм Насыйрины аерып күрсәтә. Мәгърифәтченең ирекле автор буларак нәшер ителә башлавы һәм фәнни-мәгариф гамәлләрен Европа мәдәнияте рәвешендә оештырырга омтылуы Кемперның тикшеренүендә аерым урын алып тора. Ул чорда ике фәнни даирә бер-берсеннән аерым диярлек яшәп килү сәбәпле, сизелерлек киеренкелек килеп чыга — моның үзәгендә «миссионерларда» эшләгәне өчен хыянәттә гаепләнгән К.Насыйри тора. Икенче яктан, рус-татар мәгариф системасы да аңа үз идеяләрен тормышка ашырырга җитәрлек мөмкинлек бирми. Болар һәммәсе бергә аның хезмәтләре һәм проектларының үзе исән чакта киң танылу алмавына сәбәп була, вафатыннан соң гына ул «хәзерге татар теленең атасы» дигән бәя ала. К.Насыйри хезмәтләре совет чорында да таныла, чөнки дини һәм сәяси мәгънәдә алар «нейтраль» була һәм күп тапкырлар кабатлап бастырыла».



М.Кемпер

М.Кемпер фикеренчә, «бу кешегә бөек татар мәгърифәтчесе, галим-энциклопедист, педагог һәм нашир, яңа заман татар фәненә нигез салучы булырга насыйп була». Татар иҗтимагый фикере тарихын өйрәнүче немец галиме К.Насыйрины «татар дөньяви фәненең „үзәк фигурасы“», дип атый.

Хезм.: Кемпер М. Мусульманская этика и «дух капитализма» // Татарстан. 1997. № 8; шул ук. Суфии и Ученые в Татарстане и Башкортостане. Исламский дискурс под русским господством / пер. с немецкого. Казань, 2008; шул ук. Русский язык ислама: феномен переключения кода // Реформы образования мусульман Евразии от Хусаина Фаизханова до Исмаила Гаспринского: исторический опыт и современная актуальность. М., 2015; шул ук. Sihabaddin al-Marganials Religious gelehrter // Islamkundliche Untersuchungen. Berlin, 1996.

Р.В.Шәйдуллин.

КЕЧЕ́ ЕЛГА́ УРТА́ ГОМУМИ́ БЕЛЕ́М МӘКТӘБЕ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү муниципаль бюджет уку йорты. Татарстанның Лаеш муниципаль районы Кече Елга авылында урнашкан. 1969 елда төзелә. 2024 елда 45 укучы белем ала, 13 педагог эшли. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2012).

Эшчәнлегендә татар халкының мәдәни мирасын, гореф-гадәтләрен саклап калуга, укучыларны татар педагогикасының иң яхшы традицияләре нигезендә укымышлы шәхесләр итеп тәрбияләүгә, татар теленең төрле фәннәрне укыту теле буларак яшәешен тәэмин итүгә юнәлеш тота. Экологик, патриотик тәрбиягә, һөнәр сайлау мәсьәләсенә зур игътибар бирелә. Биредә «Тарих сөючеләр оешмасы», «Яшь урманчылар мәктәбе», «Ак каурый» түгәрәге, спорт, милли көрәш секцияләре эшли. Шулай ук К.Насыйри мира-

сын өйрәнү һәм пропагандалау өлкәсендә актив эш алып барыла.

Укучылар район, республика, төбәкара, Россия күләмендә уздырылган төрле бәйгеләрдә: Каюм Насыйри исемендәге XVII (2019) һәм XX (2022) төбәкара яшьләр фәнни-тикшеренү укуларында — 2 нче, «Гомуми экологик һәм географик белем бирү концепциясе» төбәк фәнни-методик конференциясендә (2022) — 2 нче, укучыларның IV республика «Экология һәм әйләнә-тирә мохит» проекты эшчәнлеге конференциясендә (2023) 3 нче дәрәҗә дипломнар алалар; Халыкара «Җәлил укулары» әдәби бәйгесендә (2022) һәм Бөтенроссия экологик рәсем конкурсының төбәк этабында (2023) 1 нче урын яулыйлар. «Шәфкатьлелек» акцияләре вакытында Лаешта урнашкан ятимнәр йортына ярдәм оештыралар, ял көннәрендә мәчеткә «Якшәмбе мәктәбе»нә укырга йөриләр. Даими рәвештә мәктәптә «Әбием сандыгы», «Аулак өй», «Гыйффәт туташ», «Түгәрәк уен» һәм башка кичәләр уздырыла.


Каюм Насыйри исемендәге бүләк милли мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

КЕЧЕ́ ШЫРДА́Н (Югары Шырдан), татар авылы. Сәкел елгасы буенда, Яшел Үзән шәһәреннән 18 км көньяк-көнбатыштарак урнашкан. Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Кече Шырдан — бай тарихлы борынгы авыл, аның барлыкка килүе Болгар чорына барып тоташа. Авыл кырыендагы 14–15 йөзләргә нисбәтле зират моңа ачык дәлил булып тора. Тарихи язмаларда беренче тапкыр 1646 елда искә алына. Революциягә кадәрге чыганакларда Югары Шырдан исеме белән дә мәгълүм. Д.А.Корсаковның «Казан төбәгенең XVIII гасыр тарихы буенча материаллар җыентыгы»нда, төбәктәге 1771–1773 елларга караган барлык авыллар исемлеге һәм башка мәгълүматлар китерелеп, Кече Шырданда бу чорда ир-атлардан 189 ясаклы татар, 3 йомышлы һәм 52 керәшен татар яшәгәнлеге, өяз шәһәре Зөядән 17 чакрым, Казаннан 44 чакрым ераклыкта урнашкан булуы күрсәтелә.

Кече Шырдан — мәгърифәтче, галим-энциклопедист Каюм Насыйриның туган авылы. Ул, 16 яшендә белем алу максаты белән Казанга китеп барса да, туган авылы Кече Шырданга (ул вакытта Югары Шырдан) һәр җәйдә диярлек кайта. Халык белән



Каюм Насыйри кайтып йөргән йорт. 20 йөз башы.

күрешеп, сөйләшеп, аларның хәлләрен белешеп, киңәшләрен биреп китә торган була. Бу турыда Каюм Насыйрины яхшы белгән һәм хәтерләгән авылдашларыннан (Талип *Гайсин*, Гыйльман *Ногманов*, Мәсхәпҗамал *Ибәтуллина*, Гатаулла *Дусаев* һ.б.) язып алынган *истәлекләрдә* бәян ителә. Үзе дә Казан губернасының *Зөя өязе* авылларына һәм, гомумән, Тау ягындагы авылларга чыгып, иске кабер ташларындагы язуларны укый, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыя, фольклор материаллары туплый. Борынгы кабер ташларындагы язуларны өйрәнү һәм биредә яшәүче өлкәннәр белән аралашу нәтиҗәсендә Зөя өязе авыллары-

ның тарихлары буенча хезмәт туа. Зөя өязенә кергән 20 авылның тарихына караган фәнни-төбәкчелек хезмәте 1926 елда «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре» китабында дөнья күрә (кара: *«Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча)»*). Анда Югары Шырдан, Мулла Иле, Рәсбуга (Урысбага), Ачасыр, Борнаш, Борындык, Мамадыш, Бакырчы, Кошман һәм башка татар авылларының тарихы турында материаллар бар.

К.Насыйри мәгълүматлары буенча Кече Шырдан авылында агалы-энеле Сәләм, Җәгъфәр (1650 елларда), 1700 елларда һәм аннан соң Әхмәд, Җәгъфәр, Хөсәен, Габдессәләм (Әбсәләм), Хөсни, Һибәтулла, Габделкави муллалар имам булып тора. Бу мәгълүматларны галим Җәгъфәр мулла нәселеннән булган Хәмид карттан язып алган. 1859 елгы унынчы ревизия язмалары буенча авылда 1703 кеше яшәгән. Авыл халкы арасында чукындырылган татарлар да булган. Миссионер-галим Е.Маловның «Идел бассейнындагы Казан һәм кайбер башка губерналардагы керәшен татарлар турында статистик мәгълүматлар»ына караганда, 1866 елда авылда 98 ир-ат һәм 100 керәшен татар хатын-кызы яши. Авылда керәшен татарларның барлыкка килү тарихын К.Насыйри риваятьләр нигезендә аңлата. Кече Шырданның бер кешесе солдаттан котылу өчен чукынып кайта. Аңа башкалар да иярә. Авылдашларының чукынуын туктатыр өчен Җәгъфәр мулла үзенең агасы Сәләм муллага: «Инде, борадәр, әгәр дә болай карап торсак, бу бәдбәхет һәммәсе дә чукынып бетәрләр болар, мин үзем солдатка китим, син боларны дингә өйрәтеп имам булып тор», — дип, үз ихтыяры белән солдатка китә. Аннан исән-сау әйләнеп кайта һәм янә берничә ел имам булып тора. Авылның соңрак чордагы имам-хатиплары: Габденнасыйр Хөсәенов (19 йөз уртасында) һәм Габделкави Габденнасыйр улы (1864–1901 елларда) — К.Насыйриның әтисе һәм бертуганы).

1874 елда Казан губерна идарәсе технигы И.А.Александров проекты буенча Казан сәүдәгәре Габделхәй Габденнасыйров (К.Насыйриның бертуган абзасы) акчасына яңа мәчет салына. 1887 елда зурайтыла, манарасы яңартыла. Авылдашларының фольклорчы Хәмит *Ярми* тарафыннан язып алынган истәлекләренә караганда, К.Насыйри авылда мәктәп салдыра. Мәскәүдәге Мәхәммәдия мәдрәсәсенә укырга кергәч, мәктәпне Габделхәй Габденнасыйров тотып тора. Мәскәүдә укыган елларда К.Насыйри Шырданга ике тапкыр кайта. Мәскәүдә укыган елларда К.Насыйри Шырданга ике тапкыр кайта. Мәскәүдә укыган елларда К.Насыйри Шырданга ике тапкыр кайта.



Каюм Насыйри туган йорт урынында урнаштырылган истәлек тактасы.



«Каюм Насыйри» бюсты (авторы Н.И.Адылов). Музей-китапханә каршында.



Мәчет.

бер авылдашы Талип Гайсин да: «Каюм абзый безнең авылда бер мәктәп салдырды», — дип искә ала. 1903 елда К.Насыйри акчасына икенче мәхәллә мәчете төзелә (кара: «*Васыятьнамә*»), аның беренче имам-хатибы Н.С.Алкин була. Мәчет каршында мәдрәсә эшли. Мәчет 1934 елда совет хакимияте тарафыннан ябыла. 1932 елда уку өе ачыла (беренче мөдире — Хәбибулла Бикмуллин). Китапханәдә 1934–1938 елларда 800 гә якын китап-брошюра һәм газета-журнал исәпләнә. 1948–1956 елларда китапханәче булып эшләгән Флёра Гобәйдуллина үзенең истәлекләрендә бу елларда китапханәгә К.Насыйри исеме бирелү турында яза. Беренче совет дүртьеллык мәктәбе 1918 елда ачыла (укытучысы – Казанның югары башлангыч училищесын тәмамлаган Ю.С.Рәхмәтуллин). Бу чорда 90 ир бала, 55 кыз бала укый. Авылның олы яшьтәге кешеләре сөйләве буенча 1930–1931 елларда Субур Хәйрулласы дигән байның ике катлы, 24 тәрәзәле йортын җидееллык мәктәп итеп үзгәртәләр. 1978 елларга кадәр ике катлы, аннары бер катлы булып кала. 2000 еллар башына кадәр — башлангыч мәктәп, 2013 елларга кадәр китапханә эшли. Клуб бар.

Кече Шырдан авылы халкы К.Насыйригa бәйле истәлекләрне, корылмаларны кадерләп саклый. Галим үзе казыткан кое бүгенге көндә дә авыл халкын суы белән шатландыра (кара: *Каюм коесы*). 2018 елда кое төзекләндерелә. Аның янындагы таллар әлегә кадәр Каюм бабаның истәлекләрен саклый, авыл халкы сүзләренә караганда, бу йөзьяшәр агачлар шул вакытларда утыртылган һәм бер өлеше әлегә кадәр исән. Иң юан тал агачы кәүсәсенең астагы өлешендә калынлыгы 1,2 м га җитә. 2015 елда «Бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган җире — тарихи авыл — Кече Шырданны торгызу» хәйриячелек фонды (оештыручысы — «Акведук» ҖЧҖ директоры А.Н.*Гобәйдуллина*) нигезләнә, аның катнашында 2015–2017 елларда 1903 елда Каюм Насыйри акчасына салынган мәчет яңадан торгызыла, «Тал чишмәсе» (күпгасырлык тал янәшәсендә) һәм «Сабантуй чишмәсе» төзекләндерелә, 2015 елда 1941–1945 елларда Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлар истәлегенә яңа һәйкәл куела. 2018 елда — «Чәй йорты», 2021 елда К.Насыйри исемендәге музей-китапханә ачыла. Музей-китапханә каршында галимнең бюсты урнаштырылган (1997, авторы — Нәүфәл *Адылов*. Аңа кадәрге



Ике катлы мәктәп. Укытучы З.С.Кавиева укучылары белән. 1971 ел.

бюст (авторы — Вил *Шәрәфетдинов*) К.Насыйриның 150 еллыгы уңаеннан 1967 елда куелган була. Авыл янында 14–15 йөзләр Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына караган болгар зираты урнашкан (2019 елда территориясе таш баганалы койма белән



Истәлек ташы — ротонда.

уратып алына, 600 төп агач утыртыла, монумент куела). 2021 елда ТР Дәүләт Советы депутаты, ТР Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча комиссия рәисе Лотфулла Шәфигуллинның матди ярдәме белән истәлек ташы — ротонда корыла. 2023 елда плотина, 2024 елда спорт мәйданчыгы төзелә. Авыл зиратында К.Насыйриның энесе Габделкави (1835–1901) һәм аның улы Габдрахман (1896–1944) җирләнгән.



Каюм Насыйри чишмәсе. 500 еллык тал янәшәсендә.

К.Насыйриның туганы Габдрахман Габделкави улы Хөсәенов йорты 1947 елда Олы Ачасыр авылына күчерелә, анда Каюм Насыйри исемендәге *Архитектура-этнография комплексы* (1997) булдырыла. Галимнең туган йорты урынында истәлек тактасы урнаштырыла. Авылда ел саен К.Насыйри һәм аның әдәби мирасына багышланган төбәкара бәйге уздырыла.

Авылда туган күренекле шәхесләр арасында: әдәбият галиме Р.К.*Ганиева* (1932–2020); эшмәкәр, хәйрияче А.Н.Гобәйдуллина (1958 елда туган); график, нәкышьче Г.Я.Мусин (1908–1942).

Әд.: Заһидуллин И. Нәсел шәҗәрәсе кайларга илтә // Казан утлары. 2024, № 7.; Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 3 том. Казан, 2005; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Ф.Исламов. Казан. 2017; Минһаҗева Г. Авылдашлар онтымый // Шәһри Казан. 2023. 24 гыйнв.; Миңнуллин Х. Кече Шырдан үз улын онытмый // Яшел Үзән. 1997. 25 февр.; Нигъмәтуллина М. Кече Шырдан авылы галиме // Яшел Үзән. 1997. 11 февр.; Филиппов А. Каюм бабай кайтты авылга // Ватаным Татарстан. 1997. 7 март; Һадиев И. «...Юкары Шырдан иленең Габделхәй Габденнасыйр угылы...» // Идел. 1994. № 10; Шакиржанов М. Йорты да, үзе дә гасырлар кичә // Мәдәни җомга. 1997. 7 март; Ярми Х. Югары Шырдан авылында // Кызыл Татарстан. 1945. 4 февр.; Малов Е. Статистические сведения о крещённых татарах Казанской и некоторых других епархий в волжском бассейне. Казань. 1866; Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII веке, изданный под редакцией Д.А.Корсакова // Известия общества археологии, истории и этнографии. Казань, 1908.

Ф.Г.Камальтдинова.

КО́БЛОВ Яков Дмитриевич (27.04.1876, Оренбург губернасы (хәзер Чиләбе өлкәсе Бреды районы)

Амурский авылы – 1937 елдан соң), дин галиме, миссионер, педагог, илаһият магистры (1905).

Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1901), мөселманнарга һәм мәҗүсиләргә каршы миссионерлык эше алып баруда катнаша. 1908 елдан — Казан губернасының Казан өязе халык училищесы, 1914 елдан — Киев уку-укыту округы инспекторы. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

Хезмәтләре татар дини мәгариф тарихы, татарларда ислам, мариларда мәҗүсилек үсеше, ислам белеменә карый. «Казан татарларында конфессиональ мәктәпләр» (1916) китабында татар җәдиди мәктәпләренең торышын җентекләп сурәтли, халык мәгарифендә ислам һәм мөселман руханиларының ролен күрсәтә. 1910 елда Казанда дөнья күргән өч кисәктән торган «Казан татарлары мифлары» («Мифология казанских татар») әсәре эчке структурасы, андагы тикшеренү алымнары ягыннан Каюм Насыйриның «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» хезмәтенә аваздаш (К.Насыйри әсәрендәге бүленеш: «Ышанулар», «Сынамышлар», «Мәҗүси йолалар һәм әфсен-өшкерүләр», Я.Кобловныкында: «Казан татарларының уйдырма затларга ышанулары» («Верования казанских татар в баснословные существа»), «Төрле предметлар, табигать һәм кеше тормышы күренешләре буенча ышанулар, багучылык һәм күрәзәчелек итү» («Поверья, гадания и ворожба, касающиеся разных предметов, явлений природы и человеческой жизни»), «Сынамышлар» («Приметы»)). Әлеге хезмәтләр, берләштерелеп, авторлары куелып, елы күрсәтелмичә генә, Казанның «Смена» нәшрияты тарафыннан бастырып чыгарыла.

Хезм.: Антропология Корана в сравнении с христианским учением о человеке // Миссионерский противомусульманский сборник. Казань, 1905. Вып. 23; Мечты татар-магометан о национальной общеобразовательной школе. Казань, 1908; Мифология казанских татар. Казань, 1910; Насыри К., Коблов Я.Д. Мифология казанских татар. Казань (б.г.).

И.Х.Хәлиуллин.

КОРБАНГАЛИ́ЕВ Мөхетдин Хафизетдин улы (26.10.1873, Вятка губернасы Алабуга өязе Биктау авылы – 03.04.1941, Казан), педагог, тел белгече, җәмәгать эшлеклесе, профессор (1930). Хезмәт Батыры (1928), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1940).

1891, 1893–1895 елларда — *Казан татар укытучылар мәктәбендә*, 1895 елдан — Казан губернасының Мамадыш өязе Чәбия-Чүрчи, Вятка губернасының Алабуга өязе Биктау авылларында, 1901 елдан Вятка губернасының Малмыж шәһәрендә рус-татар башлангыч училищеларында укыта. 1903–1917 елларда — Казандагы Мөселман балалар приютында укытучы-күзәтче. 1907–1917 елларда — Шәрекъ клубы идарәсе әгъзасы һәм старшинасы, 1911–1917 елларда — Ярлы мөселманнарга ярдәм җәмгыяте сәркатибе. 1917 елда Казан шәһәр думасында, Казан өяз земство идарәсендә эшли, татар мәктәпләрен үзгәртеп кору мәсьәләләре белән шөгыльләнә. 1918 елдан — Казан губернасының халык мәгарифе органнарында, 1920–1928 елларда — ТАССР Мәгариф халык комиссариатында хезмәт мәктәбе бүлеге мөдире, бер үк вакытта Шәрекъ педагогия институтында, Татар педагогия техникумында һәм башка уку йортларында укыта. 1924–1927 елларда — *Гыйльми үзәк* рәисе урынбасары. 1928–1940 елларда — Казан университетында, 1930 елдан —

татар теле кафедрасы мөдире һәм профессоры, бер үк вакытта Казан педагогия институты профессоры. 1940 елдан — ТАССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтында.

1906 елдан «Азат», «Азат халык» газеталарында хезмәттәшлек итә. 1912 елда яңа җәдит мәдрәсәләр өчен уку-укыту ярдәмлекләре комплектын (татар һәм рус әлифбалары, уку өчен китаплар, «Дөнья» исемле табигать белеме, математика дәреслекләре) бастыра. 1913–1914 елларда — «Мәктәп» журналы хезмәткәре. 1920 еллар башыннан — программалар һәм уку-укыту ярдәмлекләре комплексын булдыру җитәкчесе, үзе тарафыннан эшләнгән аналитик-синтетик аваз методы нигезендә татар теленә өйрәтү методикасы авторы; башлангыч, урта сыйныфлар һәм наданлыкны бетерү курслары өчен Хуҗа Бәдигый, Галимҗан Шәрәф, Ризаэддин Газизов белән бергәләп дәреслекләр, сүзлекләр һәм методик ярдәмлекләр төзи. 1930 елларда татар телен укыту методикасын яңалиф һәм кириллица нигезендә яңадан эшли. М.Корбангалиев шул чордагы татар мәктәпләрендә рус телен укыту һәм татар булмаганнарга татар телен өйрәтү методикасын булдыруда мөһим роль уйный; Татарстан төбәген өйрәнүдә уку-укыту ярдәмлекләре, математика, география буенча рус дәреслекләренең татарчага авторлаштырылган тәрҗемәләрен бастыра. Программалар төзүдә, милли педагогик кадрлар әзерләүдә, уку процессын оештыру һәм системалар булдыруда әйдәп баручы эшлеклеләрнең берсе була. Татар теле грамматикасы проблемаларын өйрәнә, 1930–1931 елларда Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы татар фәнни терминологиясен төзү комиссиясен җитәкли.)



М.Х.Корбангалиев

М.Корбангалиев, Каюм Насыйриның укучысы буларак, аның педагогик традицияләрен дәвам итә. Телләрне өйрәнү методикасын эшләгәндә ул, беренче чиратта, туган телгә таяну принцибына нигезләнә, ягъни икенче (чит) телне өйрәнү туган телдәге белемнәрне куллану аша барырга тиеш, дип исәпли.

М.Корбангалиевнең мәгърифәтченең тууына 100 ел тулуга багышланган «Каюм Насыйри турында истәлекләр» язмасы беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасында дөнья күрә (1925). Аннан соң кайбер зур булмаган үзгәртүләр белән «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре...» дигән китапта бастырыла. Әлеге хатирәсендә К.Насыйриның фәнни-педагогик, тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге, яшәү шартлары һәм холкы, тышкы кыяфәте, кайбер хезмәтләре хакында бәян ителә, аны үзенең остазы дип атый. 1889 елда, Казанга килеп, Татар укытучылар мәктәбенә керүен, анда рус телен тырышып өйрәнүен, К.Насыйри белән очрашуын, мәгърифәтченең аның русча укый башлаганчы мөселманча кайда өйрәнүе турында сорашуын, аңа үзе җыйган җырларны, бәетләрне алып баруын һәм аның, картларны җырлатып, сөйләтеп, ядкәр-истәлекләр җыярга, бигрәк тә алпавытлар кулында крестьннарның ничек яшәгәнлек хәбәрләрен үзләштерегә кушуын искә ала. Иң мөһиме К.Насыйридан телебезнең фонетикасы һәм сарыфы турында күп мәгълүмат алуын, 1895 елда, мәктәпне тәмамлап, Мамадыш өязенә укытучы булып баргач та, русча китап-

лар белән беррәттән К.Насыйри китапларыннан файдалануын, балаларны «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»тан өзекләр алып укытуын искәртеп үтә. Мәгърифәтченең ун мәддәле [сузык аваз хәрефләре] имлясын утыз еллык эшчәнлегендә гамәлгә ашырырга тырыша, «Татарча әлифба», «Татарча уку» китапларын, хисап дәреслекләрен төзеп тарата, әсәрләренең әһәмияте һичкайчан югалмас дип нәтиҗә ясый, «Менә Насыйри абзый, синең васыять итеп калдырган юлыңда мин утыз ел эшләдем. Минем кебек синең юлыңда эшләүчеләр бик күп булдылар. Хәзер без синең васыять итеп калдырган әсәрләреңне үткен коралларга әйләндереп бетердек», — дип яза.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Хезм.: Олылар өчен рәсемле татар әлифбасы. Казан, 1920; Олыларны укырга өйрәтү юллары һәм дәрес бирү үрнәкләре. Казан, 1921 (Х.Бәдигый белән автордаш); Укый-яза белмәүчелекне бетерү мәктәпләрендә укытучылар өчен кулланма. Казан, 1924; Каюм Насыйри турында истәлекләр // Кызыл Татарстан, 1925. 15 февр.; Крестьян әлифбасы. Казан, 1925; Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга. Казан, 1926.

Әд.: Вәлиева Ф.С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевнең татар телен укыту буенча методик системасы. Казан, 2004; Ханбиков Я.И. Мөхетдин Корбангалиевнең төп фәнни хезмәтләре исемлеге // Фән һәм тел. 2000. № 2; Асадуллин А.Ш. Заглядывая в прошлое методической науки: Из методического наследия по преподаванию русского языка в национальной школе. Казань, 2001; Ханбиков Я.И. История педагогической мысли татарского народа. Казань, 1975.

Ф.С.Гыйниятуллина, И.Х.Хәлиуллин.

КОРБА́НОВ Тәһир Яхъя улы (25.09.1910, Оренбург губернасының Кашерин өязе (хәзер Оренбург өлкәсенең Шарлык районы) Мостафа авылы – 16.01.2014, Казан), педагог, педагогика фәннәре кандидаты (1956). ТАССРның атказанган укытучысы (1971). Бөек Ватан сугышында катнаша.

Авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1926–1930 елларда Оренбург педагогия техникумында белем ала. Соңрак Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген (1941) тәмамлый. 1930–1933 елларда — Мостафа авылы мәктәбендә укытучы һәм мөдир, 1933–1936 елларда Шарлык район мәгариф бүлеге инструкторы булып эшли. 1942 елда — Ленинград хәрби училищесы курсанты. 1945–1946 елларда ТАССР Югары Советы инструкторы вазифасын башкара. 1946–1986 елларда Казан педагогия институтында: педагогика кафедрасы аспиранты, ассистенты, өлкән укытучысы, доценты, кафедра мөдире.

Хезмәтләре татар педагогикасы тарихына, милли тәрбия мәсьәләләренә карый. Акыл ияләре, аларның педагогик эшчәнлеге хакында Казан, Мәскәү матбугатында чыгышлар ясый. Аның А.С.Макаренко, В.Г.Белинский, К.Д.Ушинский, Каюм Насыйри, Галимҗан Ибраһимов, Гафур Коләхмәтовның педагогик карашлары һәм эшчәнлекләре турындагы хезмәтләре зур әһәмияткә ия.

К.Насыйриның тууына 115 ел тулу уңаеннан язылган мәкаләсе 1940 елда «Совет мәктәбе» журналында дөнья күрә. Ул анда мәгърифәтче галимнең гыйльми эшчәнлеген әтрафлы яктырта. Барыннан да бигрәк К.Насыйри фәнни эшчәнлегенең татар әдәби телен үстерүгә, аның үсеш юлларын билгеләүгә, татар грамматикасын булдыруга, татар халык авыз иҗатын

җыеп, фәнни җирлектә өйрәнүгә юнәлтелгән булуына басым ясый. Шул ук вакытта аның иҗат даирәсенең тел, әдәбият белән генә чикләнмәгәнлеген, күп кенә башка фән тармакларын да колачлавын, сүзлекләр төзүен билгеләп үтә, һәрдаим гыйлем-мәгърифәткә омтылуын һәм татар халкын да мәгърифәтле итәргә тырышуын, рус телен өйрәнү һәм өйрәтү кирәклегенә зур игътибар бирүен, гомумән, гомерен фәнгә һәм мәгарифкә багышлаган бөек шәхес булуын ассызыклый.



Т.Я.Корбанов

«1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри һәм аның гыйльми хезмәтләре // Совет мәктәбе. 1940. № 2–3; Беренче рус революциясе чорында татар укучы яшьләре хәрәкәте // Совет мәктәбе. 1956. № 1; Татарларда беренче педагогик уку йорты // Совет мәктәбе. 1973. № 2.

Әд.: Әхмәтҗанов М. Мәгърифәткә багышланган гомер // Мәгариф. 2004. № 2; Хузиахметов А.Н., Ахметзянов М.Р. Славный путь педагогов // Музейный вестник ТГГПУ. Казань, 2006. Вып. 3.

Ф.С.Гыйниятуллина.

«КӨНБАГЫШКА́Й» СИКСӘ́Н ИКЕНЧЕ́ БАЛАЛА́Р БАКЧАСЫ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү оешмасы. 1979 елда Чаллы шәһәрендә ачыла. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2015).

Эшчәнлегендә балаларны халык иҗатына җәлеп итү һәм аларда мәдәнияткә, халык традицияләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү аша туган телне (татар телен) өйрәтүгә, милли үзаң, үз халкына карата мәхәббәт, әхлакый сыйфатлар формалаштыруга юнәлеш тота. Каюм Насыйриның туган көненә багышланган тематик кичә, әзерлек төркемнәрендә «Каюм Насыйри хикәятләре белән танышу» тематик дәресе, педагоглар белән «Каюм Насыйри иҗатында татар халык тәрбиясе» түгәрәк өстәле, «Каюм Насыйри иҗаты һәм бабалар тәрбиясе» темасы буенча педагогик семинар, тәҗрибә туплау мәйданчыгы кысаларында галимнең тормышы, иҗаты һәм фәнни хезмәтләре чагылдырылган «Каюм Насыйри мирасы» кичәсе уздырыла; «Шәһри Чаллы» газетасында «Каюм Насыйри — күпкырлы шәхес», «Каюм Насыйриның фольклор өлкәсендәге эшчәнлеге», «Халкыбызның горурлыгы» язмалары басыла.



Сиксән икенче «Көнбагышкай» катнаш төрдәге балалар бакчасы.

«Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» республика (2017; уку-укыту–методик комплекс кысаларында мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ТР дәүләт телләрен өйрәтү буенча тел мохите булдыру), «Балаларны туган (татар, чуаш, удмурт, мари, мордва) телдә укыту һәм тәрбияләүне оештыру буенча иң яхшы балалар бакчасы» (2020; мәктәпкәчә яшьтәге балаларда туган телдә (татар те-

лендә) бәйле сөйләм һәм рухи-әхлакый сыйфатлар формалаштыру), «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның телләрен, традицияләрен, мәдәниятләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән проектларны гамәлгә ашыруда муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына ярдәм итү» (2022; татар халкының телен, мәдәниятен, традицияләрен саклау һәм үстерү), «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» (2022; ТРда ике телле шәхес формалаштыру шартларында балаларга үзара бәйләнешле рус һәм татар телләрен өйрәтү) конкурсларында җиңүче, һөнәри «Ел тәрбиячесе — 2021» (2021; «Туган телдә тәрбияләү һәм укыту тәрбиячесе — 2021» номинациясе), «Ел тәрбиячесе — 2024» (2024; «Туган телдә тәрбияләү һәм укыту тәрбиячесе — 2024» номинациясе) конкурслары лауреаты.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк милли мәгарифне үстерүдәге казанышлары өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

«КРА́ТКАЯ ТАТА́РСКАЯ ГРАММА́ТИКА» («Нәхү китабы»), татар теле грамматикасы кагыйдәләре буенча русча-татарча язылган уку-укыту әсбабы (1860). Китапның титул битендә түбәндәге аңлатма язуы бирелгән: «Урысча үгрәнүче татар егетләре өчен вә һәм татарча үгрәнүче урыс егетләре өчен тасниф кылдым Габделкаюм Габденнасыйр угылы».

Хезмәт төп дүрт бүлеккә бүленгән: 1. Язу һәм татар телендә уку (Письмо и чтение в татарском языке); 2. Телнең лексик составы (Лексический состав языка); 3. Телнең флексик формасы (Флексическая форма языка); 4. Татар телендә сүз ясалышы кагыйдәләре (Правила словосочинения в татарском языке). Беренче бүлектә гарәп графикасы нигезендәге татар теле хәрефләре, аларның кушылып һәм аерым язылу системасы, сузык һәм тартык аваз-ларны белдерүче хәрефләр, хәрәкәләр, гарәп теленә генә хас булган хәрефләр, сузыклар куелмыйча языла торган сүзләр, хәрефләрнең язуда үзгәрүе (андан = аннан), сөйләмдә сузык аваз-ларны белдерүче хәрефләрнең кушылып китү очраклары (яңа ай = яңай);



К.Насыйри. «Краткая татарская грамматика = Нәхү китабы». Казань, 1860.

икенче бүлектә сүз төркемнәре (исем, сыйфат, фигыль, алмашлык, сан, теркәгеч, ымлык), аларның үзенчәлекләре; өченче бүлектә сүз төркемнәренең төрләнеше; дүртенче бүлектә җөмлә төзелеше, идиомалар, изафә күренешләре өйрәнелә. Ахырда уку күнекмәсе өчен дүрт хикәя китерелә.

Чыг.: Насыйри К. Краткая татарская грамматика = Нәхү китабы. Казань, 1860.

Р.Ф.Исламов.

КУЛЪЯЗМАЛА́Р ҺӘМ СИРӘ́К КИТАПЛА́Р БҮЛЕГЕ́, Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең структур өлеше. 1837 елда архитек-

тор М.П.Коринфский проекты буенча төзелгән бинада урнашкан.

Бүгенге көндә университет китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге Шәрекъ кулъязмалары һәм китаплары, Көнбатыш Европа, рус кулъязмалары һәм китаплары секторларыннан тора. Анда рус, татар, гарәп, фарсы һәм башка телләрдәге 9–20 йөзләргә караган кулъязмалар һәм кулъязма китаплар саклана. Россия һәм СССР матбугатыннан 19–20 йөз басмалары аеруча тулы тупланган, 18 йөз китаплары һәм журналлары зур урын алып тора. Бүлектә Каюм Насыйриның кулъязма дәфтәрләрдән гыйбарәт тел белеме, матур әдәбият, тарих, археология, география, математика һәм ислам дине мәсьәләләренә, дәреслекләргә, календарьлар эшләүгә, шәҗәрәләр төзүгә, аш-су әзерләүгә һәм башка темаларга караган алты дистәдән артык кулъязмасы (аларның берише төрле күләмдә кабатлана), өч йөз егермедән артык хаты саклана. Әлеге кулъязмаларның бер өлеше Казан университеты Фәнни китапханәсенә И.Ф.*Готвальдның* шәхси китапханәсе белән бергә килеп керә.

Тел галиме Мостафа *Ногман,* К.Насыйри мирасыннан шундагы 84 саклау берәмлеген барлап, өйрәнеп, 1958 елда китап белгече Әбрар *Кәримуллин* мөхәррирлегендә Казан университеты нәшриятында өч кисәктән торган «Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. Каюм Насыйри кулъязмалары» хезмәтен дөньяга чыгара. Тасвирламадагы саклау берәмлекләре исемлегендә Каюм Насыйриның татар һәм гарәп телләре грамматикасы, татар теленең аңлатмалы сүзлеге, шулай ук экологиягә, матур әдәбиятка, тарих-археологиягә, ислам диненә, ботаникага (үләннәр һәм чәчәкләр), Казан календарьларына, география, арифметика буенча дәреслекләргә һәм башка фәнни-практик мәсьәләләргә караган төрле эчтәлекле язмалар китерелгән. Анда К.Насыйриның, аның атасы, туганнары, карендәшләре һ.б.ның төрле эчтәлектәге хатлары тасвирланган (Тулырак кара: *Кушымта 2*). Әлеге исемлектә К.Насыйри тарафыннан 1886 елда язып тәмамланган, 130 ел буе китапханә киштәсендә яткан, ислам гыйлемендә әлегәчә кыйммәтен һәм әһәмиятен югалтмаган кулъязма хезмәт — «*Мифтах әл-Коръән*» [«Коръән ачкычы»] — татар дөньясында Коръәннең беренче белешмәлек-конкордансы да китерелә. Ул 2016 елда ике китап булып басылып чыга. Аның беренчесе — «Калям Шәриф», Коръәннең К.Насыйри тарафыннан файдаланылган 1861 елгы Казан басмасының факсимиле; икенче китабы — «Мифтах әл-Коръән» кулъязмасының факсимиле.

Мостафа Ногман тасвирламасында галимнең 1884–1899 елларда дөнья күргән егермедән артык хезмәте китерелә. Кара: *Кушымта 2*.

Әд.: Ногман Мостафа. Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. II чыгарылыш. Каюм Насыйри кулъязмалары. Казан, 1958; Фәтхи Альберт. Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы / V чыгарылыш. — Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. — 1 бүлек. Казан, 1960; шул ук. Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы / X чыгарылыш. — Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. — 2 бүлек. Казан, 1962; Шәфигуллина Р.Ф., Хәйретдинов А.Г. Каюм Насыйриның 130 еллык кулъязмасы: Коръән өйрәнү тарихы // Татарское рукописное наследие: Материалы всероссийской научно-практической конференции, посвященной 130-летию С.Вахиди. Казань, 2017; Миннуллин З.С. Восточная


археография в Казанском университете: страницы истории // Тюрко-мусульманский мир: идентичность, наследие и перспективы изучения (к 80-летию профессора М.А.Усманова). Казань, 2015.

И.Х.Хәлиуллин.

КУРБА́ТОВ Хәлиф Рәхим улы (28.02.1927, Татарстанның Минзәлә кантоны (хәзер Актаныш районы) Иске Богады авылы – 16.07.2005, Казан), тел галиме, филология фәннәре докторы (1993).

Пермь университетын тәмамлаганнан соң (1950), СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзер ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) аспирантурада укый һәм шунда 1953 елда эшкә калдырыла.

Хезмәтләре татар тел белеменең төрле тармакларына карый. Аның фәнни-тикшеренү эшчәнлеге берничә юнәлешкә бүленә. Беренчесе — татар орфографиясе һәм орфоэпиясе. Бу проблемага ул «Татар теленең алфавиты һәм орфографиясе» (1958), «Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы» (1960) хезмәтләрен багышлый. Соңгысында татар язуының тарихы рун язуларыннан башлап хәзерге вакытка кадәр тасвирлана. Икенче юнәлеш — татар теленең стилистикасы. Әлеге тармак буенча күпсанлы мәкаләләре, татар һәм рус телләрендә «Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы» (1971), «Татарская лингвистическая стилистика и поэтика» (1978), «Сүз сәнгате: татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы» (2002) хезмәтләре дөнья күрә. Өченче юнәлеш — татар әдәби теленең тарихы, шул исәптән, борынгы, урта гасырлар һәм яңа заман шигъриятенең метрик системасы (силлабика һәм гаруз). Бу өлкәдәге тикшеренүләре татар һәм рус телләрендәге «Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика» (1984), «Шигырь энҗеләре ничек барлыкка килә?» (2002), «Ритмика татарского стиха» (2005) хезмәтләрендә чагылыш таба.



Х.Р.Курбатов

Каюм Насыйриның тууына 130 ел тулу уңаеннан «Яшь сталинчы» газетасының 1955 ел 16 февраль санында басылган «Атаклы галим, педагог һәм мәгърифәтче» мәкаләсендә галимнең күпкырлы эшчәнлеген яктыртып, аның турында: «Ана телен әдәбият теле дәрәҗәсенә күтәрүдә, тарих, этнография һәм фольклор материалларын туплауда гаять киң колачлы эшчәнлек күрсәткән универсаль галим; татарларга төрле-төрле фәннәрне, рус телен өйрәтүнең, уку-укыту, тәрбия эшләре алып баруның нигезен салган атаклы педагог, тәрҗемәче һәм язучы», — дип яза. Шулай ук, «Әнмүзәҗ», «Краткая татарская грамматика» китапларына, «Әбугалисина», «Кырык вәзир кыйссасы», «Буш вакыт» әсәрләренә, «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» хезмәтенә кыскача анализ ясап, аларның әһәмиятен билгели. Аның педагогик карашларының Константин Ушинский, Лев Толстой йогынтысында формалашуына басым ясый. Ул чыгарган календарьларның киң гавамга аң-белем бирүгә юнәлдерелгән булуын билгеләп үтә. Галимнең русча-татарча, татарча-русча сүзлекләре, математика, география һәм башка фәннәргә караган хезмәтләре дә аның игътибар үзәгенә алына.

«Почёт билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Атаклы галим, педагог һәм мәгърифәтче (К.Насыйриның тууына 130 ел тулу уңае белән) // Яшь сталинчы. 1955. 16 февр.; Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. Казан, 1956; Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан, 1960; Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М., 1978.

Әд.: Бәширова И. Күпкырлы галим // Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. Казан, 2011; Zaripova-Çetin Ç. Helif Kurbatov // Türkiye Dışındaki Türk Dünyası Türkologları: Dilciler. İstanbul, 2019. 2 Cılt.

И.Х.Хәлиуллин.

«КЫРЫ́К БАКЧА́», дидактик эчтәлекле хикәятләр, мәсәлләр, мәзәкләр җыентыгы. Каюм Насыйри тарафыннан тәрҗемә ителеп, 1880 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә.

Җыентыкның исеме күренекле гарәп галиме әз-Зәмәхшәри Габделкасыйм Мәхмүд ибне Гомәр (1074–1144) әсәре буенча бирелгән һәм бүлекләр раузаның тәрҗемәсеннән бакча дип аталган. Анда кешенең тормышына, көнкүрешенә караган хәл-вакыйгалардан, өйрәнергә һәм сакланырга тиеш булган гадәтләрдән мисаллар китерелә. Бакчалар (бүлекләр) акыл, гыйлем, әдәп, фирасәт (зиһен), тугрылык һәм башка кыйммәтләрне күрсәтүгә багышлана, шулай ук ахмаклык, куркаклык, икейөзлелек кебек тискәре сыйфатлар тәнкыйтьләнә. Хикәятләрдә китерелгән «...Һәрбер нәрсәнең чиге бар, акылның чиге юк», «Кеше үзен-үзе таныса, камил акылы шуннан беленер», «Әгәр дә бер адәм белән мосахәбәт кылсаң (юлдаш булсаң), аның акылына кара, диненә карама», «Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне үзең үгрәт...», «Олуглык акыл белән, әдәп белән, әмма нәсел белән, нәсәп белән түгелдер» һәм башка афоризмнар хәзерге вакытта да актуаль. Ахырда төрле эчтәлектәге ун шигырь урын ала. Чынлыкта ул галимнең «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше») (1884) хезмәтенең беренче варианты.

Китапның икенче басмасы 1902 елда Казанда матбагаи Кәримиядә (кара: *Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф кою ширкәте*) нәшер ителә. Кыскартылган тексты К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»ендә (1953), «Әсәрләр»ендә (1971), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томында (1975) урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Кырык бакча. Казан, 1880.

Әд.: Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Мөхәммәтов Х. Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеяләре. Казан, 1961.

Р.Ф.Исламов.

«КЫРЫ́К ВӘЗИ́Р КЫЙССАСЫ́», төрле мәҗаралы хикәятләр тупланган дидактик жанрдагы җыентык. Каюм Насыйри тарафыннан госманлы төрек телендә ниндидер Мостафа ханга багышлап язылган китаптан тәрҗемә ителеп, 1874 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә.

Чыганагы борынгы һинд әдәбиятына барып тоташкан кыйссалар башта фарсы дөньясында «Синдбаднамә», аннары гарәпләрдә «Әрбагыйн собых вә маса» («Кырык иртә һәм кичә кыйссасы») буларак таныла. Эчтәлеге белән «Мең дә бер кичә» әсәренә охшаш. Җыентыктагы хикәятләр гаделлек, тугрылык, намуслылык, батырлык идеяләрен яклауга юнәлдерелгән.



К.Насыйри. «Кырык вәзир кыйссасы». Казан, 1874.

Кыйссада бер олуг падишаһның хатыны аның икенче хатыннан туган улын, нахакка гаепләп, хыянәтче итеп күрсәтә. Падишаһ, аны үтертергә карар кылып, һәр иртәдә үлем җәзасын башкартырга китерткәндә кырык вәзирнең берсе хикәят сөйләп, бәлане кичектерә. Ә хатын исә, һәр кич иренә хикәят сөйләп, аны янә ачуландырып, карарын үтәргә күндерә. Эшнең ничек тәмамланганы китапта шулай бәян ителә: «Кырык көннән соң угылының тугрылыгы беленеп вә мәккярә [ялганчы] хатынның ялганчылыгы заһир булып [ачыкланып], җәзасыны тапты вә угылы дәхи атасы янында сәвекле булып, хәленең ничек икәне мәгълүм булды». Шулай итеп, явызлык җиңелә, хакыйкать тантана итә.

Чыганакларда китапның 8 басмасы булуы күрсәтелсә дә, Казан китапханәләрендә аның Әхмәтсафа Хәмзиннең матди ярдәме белән Казан университеты басмаханәсе нәшер иткән (1891), Исмәгыйль Шәмсетдинов бастырган (1900, 1908, 1910) нөсхәләре саклана. Әсәрнең кыскартылган тексты К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»ендә (1945, 1953, 1956), «Әсәрләр»ендә (1971), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томында (1975), дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең 1 нче томында (2003) урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Кырык вәзир кыйссасы. Казан, 1874.

Әд.: Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Мөхәммәтов Х. Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеяләре. Казан, 1961; Катанов Н. Кырык везир кыссасы (Сказки 40 везирей). Казань: Тип. ун-та, 1900. 160 стр. // Деятель. 1901. № 5.

Р.Ф.Исламов.

Л

«ЛӘҺҖӘЙ ТАТАРИ́», татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Татар лексикографиясенә караган тәүге сүзлек. Каюм Насыйри тарафыннан төзелә һәм 1895–1896 елларда Казан университеты басмаханәсендә ике кисәккә бүлеп нәшер ителә.

«Ләһҗәи татари» билгеле бер дәвердәге татар әдәби теленең лексикасын җыю, аны системалаштыру һәм сүзләрнең мәгънәләрен җентекле тикшерү юнәлешендә татар әдәби телен баету-үстерү максаты белән башкарылган. Моңа аңлатма биреп, галим үзе болай яза: «...бу заманымызга кадәр татар телемезгә хезмәтчеләр була килмәгәнлек сәбәпле, татар телемез артта, гаять бәгыйдь [ерак] йоклап калмыштыр». Сүзлек гамәли яктан сүзләрнең лексик-семантик һәм стилистик кулланышларын чагылдыра, фәнни яктан сүзләрнең этимологиясе һәм грамматик категорияләре турында мәгълүмат бирә. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, «Ләһҗәи татари»га ун мең чамасы аерым сүз, халык авыз иҗаты үрнәкләре тупланган.

Сүзлекне төзү барышында түбәндәге алымнар кулланылган: сүзләрне турыдан-туры татарча яки татарчалашкан адекватлары яки синонимнары белән аңлату; гарәп, фарсы сүзләре белән генә яки синонимнары белән аңлату; татар, рус, гарәп сүзләре белән тәрҗемә итү; сүзнең аныклы синонимнары, адекватлары яки яраклы тәрҗемәләре табылмаганда, аларга киңәйтелгән аңлатмалар бирү; сүзләрнең мәгънәләрен һәм мәгънә төсмерләрен ачыклау, аныклау, аларның кулланышларын күрсәтү өчен иллюстрация материалларыннан (мәкаль-әйтемнәр, җырлар, фразеологик тәгъбирләр һ.б.) файдалану.


لهجة تاتار

КАЗАНЬ.
Типо-литография Императорскаго Университета.
1895.

К.Насыйри. «Ләһҗәи татари». Казан, 1895, 1896.

Тюрколог М.П.Мелиоранскийның «Ләһҗәи татари» турында төрек галиме Әхмәт Рәфыйкның 1876 елда басылган «Ләһҗәи госмани» хезмәтеннән күчерелгән дигән фикере сүзлектә госманлы төрек сүзләренең булмавы белән кире кагыла. Р.*Фәхретдинов* К.Насыйригa багышлап язган мә-

каләсендә: ««Ләһҗәи татари» «Словарь татарского языка» әсәре илә «Лөгате чыгтай вә төрки госмани» исемле китаптан алынмыш вә үз иҗтиһады [тырышлыгы] илә бик күп шәйләр җыелмыш исә дә, тел вә лөгать фәнни сурәттә тәфсир ителмәмештер», — дип, галимнең үзе тарафыннан да бик күп материал туплангалыгын раслый.

Чыг.: Насыйри К. Ләһҗәи татари. Казан, 1895, 1896.

Әд.: Фәхретдинов Р. Габделкаюм Насыйри // Шура. 1912. № 21; Хангилдин В. Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Катанов Н. «Легдже-и татари» (толковый татарский словарь). Часть I, 1895. 226 стр. в 6 д. л. Часть II, 1896. 106 стр. в 6 д. л. Тип. ун-та / Н. Катанов // Деятель. 1897. № 3.

Р.Ф.Исламов.

ЛЕ́БЕДЕВА (Барщёва) Ольга Сергеевна, кара: *Гөлнар ханым*.

ЛЕКСИКОГРА́ФИЯ (грек теленнән lexikos — сүзлек һәм graphein — язу), тел белеменең сүзлекләр төзү теориясен һәм практикасын тормышка ашыручы тармагы. Практик лексикография (сүзлек эше) иҗтимагый әһәмияткә ия функцияләр башкара; ул телләр өйрәнү (туган тел, чит телләр), туган телне тасвирлау һәм нормага салу өчен, телара аралашу чарасы буларак, теге яки бу телнең сүзлек составын (лексикасын) фәнни яктан өйрәнү өчен кирәк.

Лексикография үсешендә төрле халыкларда, шул исәптән татарларда да 2 чорны аерып өйрәнәләр: 1. Иң әүвәлге сүзлекләр чорына (11–18 йөзләр) татар теленең безнең заманнарга килеп җиткән иң борынгы сүзлекләре карый: Мәхмүд Кашгаринең «Диване лөгатет эт-төрк» («Төрки телләр сүзлеге», 1072–1074), «Төрки, монгол, фарсы һәм башка телләр сүзләрен туплаган тәрҗемә сүзлек китабы» («Китабе мәҗмуге тәрҗемане төрки вә гаҗәми вә магули вә фарси», 1245), «Төрки телләргә аңлатмалар бирү китабы» («Китаб әл-идрак ли-лисан әл-әтрак», 1312), Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булатның «Гарәпчә-төркичә-татарча сүзлек» китабы (16 йөз), «Кодекс Куманикус»ы һ.б.; 2. Лексикография зур үсеш алган чорда (19 йөз башы) телнең сүзлек составын тасвирлау һәм нормага китерү, җәмгыятьнең тел культурасын күтәрү бара; төрле, шул исәптән орфографик, грамматик, аңлатмалы, фразеологик сүзлекләр чыга башлый.

Татар лексикографиясендә сүзлекләр, шул исәптән терминологик сүзлекләр төзү аеруча өйрәнелгән юнәлеш булып тормый. Аңа 19 йөзнең 2 нче яртысында Каюм Насыйри тарафыннан нигез салына. Татар сүзлекләренең 1878 елда «Татарча-русча лөгать китабы» һәм 1892 елда «Русча-татарча сүзлек» («Полный русско-татарский словарь») дип аталган беренче басмалары дөнья күрә. Әлеге сүзлекләр өстендә эшләгәндә әдип русларга — татар телен, татарларга рус телен өйрәтү максатын алга сөрә, шул рәвешле ул, кыскача гына Россия тарихы һәм ике халыкны бер-берсенең мәдәниятләре белән таныштыруда ачкыч булдыруга омтылып, аларны үзара тагын да якынайтуга зур өлеш кертә. Аның татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзү тәҗрибәсе В.Н.*Хангилдин*, Ә.Ш.*Юсупова* һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла.

1895–1896 елларда К.Насыйриның ике томлык «Ләһҗәи татари» хезмәте — татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге дөнья күрә. Ул татар лексикографиясе өлкәсендә беренче башлап төзелгән аңлатмалы сүзлек. Аны эшләргә алынганда әдип татарларга

һәм башка кызыксынучыларга шул чор татар әдәби телен өйрәтү һәм татар әдәби телен лексик-стилистик җәһәттә баету бурычын куя. Сүзләрне аңлатуда ул төрле материал һәм чаралардан файдалана, берничә төрле алым (сүзләрне турыдан-туры татарча яки татарчалашкан ишләре яисә синонимнары белән аңлату; гарәп, фарсы сүзләре белән генә, яки алар белән татар сүзләрен дә аралаштырып тәрҗемә итү; татар, рус һәм гарәп сүзләре белән тәрҗемәләү; сүзнең анык синонимнары яки яраклы тәрҗемәләре табылмаганда аңлатмалар бирү; сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау, аларның кулланылган урыннарын күрсәтү өчен күп кенә мисаллар, иллюстрация материаллары файдаланылу) куллана.

В.Н.Хангилдиннең 1948 елда дөнья күргән гыйльми сессия материаллары җыентыгында урнаштырылган «Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе» дип аталган мәкаләсендә галим төзегән сүзлекләрнең татар әдәби теле үсеше һәм алдагы чорларда барлыкка килгән сүзлекләр өчен ышанычлы җирлек булу әһәмияте ассызыклана, аерым алганда, «Ләһҗәи татари» татар телен тарихи үсешендә өйрәнү юлында, аеруча аның лексика өлкәсен өйрәнү өчен бердәнбер тулы чыганак буларак бәяләнә. К.Насыйриның терминологик сүзлекләре исә (фәннең төрле тармаклары буенча кулъязмалар хәлендә сакланган латинча-гарәпчә биология терминнары сүзлеге, татарча-латинча-русча ботаника терминнары сүзлеге, татарча биология терминнары сүзлеге, русча-латинча-татарча ботаника терминнары сүзлеге, гарәпчә-татарча-латинча гомуми терминнар сүзлегенең башлангычы) татар әдәби телен лексик яктан нормалаштыру максатын күздә тота.

К.Насыйриның лексикографик хезмәтләре 1920–1930, 1970–1990 елларда аеруча икътисад, җитештерү һәм мәдәниятнең барлык тармаклары буенча дөнья күргән 70 тән артык сүзлек өчен җитди нигез булып торалар. Татар лексикографиясе мәсьәләләре, шул исәптән К.Насыйриның бу өлкәдәге мирасы Ф.Ә.Ганиев, Ф.С.*Сафиуллина,* М.Н.*Ногман*, Д.Б.Рамазанова, В.Н.*Хангилдин*, Ш.С.*Ханбикова*, Ә.Ш.Юсупова һ.б.ның хезмәтләрендә тикшерелә.

Әд.: Миңнуллин К., Вәлиуллин Р. Татар теле — сүзлекләрдә. Казан, 1998; Ногман М. XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кулъязма сүзлекләр. Казан, 1969; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан, 2006; Хангилдин В. Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Компьютерная лингвография. Казань, 1995; Юсупова А.Ш. Вклад К.Насыри в создание татарско-русских и русско-татарских словарей // Востоковедение в России и странах СНГ на рубеже веков: материалы международного симпозиума, посвященного 200-летию создания кафедры восточной словесности в Казанском университете. Казань, 2015; шул ук. Об одном словаре Каюма Насыри // Татарская поэзия и культура второй половины XX — начала XXI века: диалог с западными и восточными художественными традициями (к 80-летию татарского поэта Рената Хариса): материалы международной научно-практической конференции. Казань, 2021.

И.Х.Хәлиуллин.

ЛЕМЕРСЬЕ́-КЕЛЬКЕЖЕ́ Шанталь (28.06. 1926, Франциянең Руан округы Ивето шәһәре – 13.06.2018, Руан шәһәре), француз тарихчысы, шәркыятьче галимә, язучы.

Лемерсье-Кельжеже Россиянең урта гасырлар, яңа һәм иң яңа тарихы-

ның төрле мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр авторы. Галимәнең тарихчы (советолог) Александр Беннигсен белән СССР төрки халыкларын һәм Үзәк Азиядәге Исламны өйрәнүгә багышланган уртак язмаларында Россия империясендә мөселман милләтчелеген өйрәнүгә зур игътибар бирелә. «Советлар Союзында ислам» (1966) монографиясе аларның уртак эшчәнлегенең әһәмиятле фәнни нәтиҗәсен тәшкил итә, авторлар анда СССР шартларында исламның көндәлек тормышта дини йола-тәртипләр рәвешендә тормышка ашырылу үзенчәлекләрен, шулай ук мөселман халыкларының гаилә гореф-гадәтләрен һәм йолаларын җентекләп тикшерәләр. Аларның тикшеренүләре нәтиҗәсендә Россия исламы Көнбатыш Европа фәне даирәсенә үтеп керә.

Үз хезмәтләрендә галимә шулай ук төрки халыклар арасында мөселман дине башлыкларының реформаторлык эшчәнлеген дә өйрәнеп тасвирлый. Мәсәлән, Лемерсье-Келькеже бер мәкаләсен татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйригa багышлап, аның турында биографик материал һәм хезмәтләренең библиографиясен урнаштыра. Мәкаләдә К.Насыйри яшәгән һәм иҗат иткән тарихи чорга зур игътибар бирелә, мәгърифәтченең киңкырлы эшчәнлеге татар җәмәгатьчелеге арасында барган актив иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни үзгәрешләр фонында характерлана. Француз тикшеренүчесе фикеренчә, мәгърифәтче галимнең татар мәгариф системасын реформалаштыру, фикердәшләр тәрбияләү юнәлешендәге фидакарь хезмәте татар яшьләренең иң алдынгы вәкилләренә белем алуларын Россия империясе уку йортларында дәвам итәргә мөмкинлек бирә, бу исә соңыннан фән һәм мәдәниятне дөньякүләм казанышлар белән баетуга, аларны кешелек



Ш.Лемерсье-Келькеже

дөньясының уртак кыйммәтләренә әйләндерүгә юл ача. Шул ук вакытта галимә К.Насыйри иҗади мирасының халык массалары аңын уятудан тыш, соңрак чорда пәйда булган фикер ияләре, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләренең тулы бер буыны формалашуда да гаять зур роль уйнавын, татар әдәбиятының Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов кебек күренекле вәкилләренең әдәбият мәйданына чыгуында аның хәлиткеч йогынтысын ассызыклый. Лемерсье-Келькеже, совет тарих фәненнән аермалы буларак, әдипнең милли-мәдәни мирасын бәяләү мәсьәләсендә мәгърифәтчелекне дә үз эченә алган дини реформаторлыкны иң беренче урынга куя.

Чыг.: Lemercier-Quelquejay Ch. Un réformateur tatar au XIXe siècle: ʻAbdul Qajjum Al-Nasyri // Cahiers du monde russe et soviétique. 1963. Vol. 4. № 1–2.

Әд.: Мусульмане в СССР // Панорама-Форум. 1995. № 2; Bennigsen A., Quelquejay Ch. The Evolution of the Muslim Nationalities of the USSR and their Linguistic Problems. Oxford, 1961; шулар ук. Les mouvements nationaux chez les musulmans de Russie. Paris, 1960. VI; шулар ук. Islam in the Soviet Union. London, 1970.

Р.В.Шәйдуллин.

ЛОТФИ́ (Лотфуллин) Гасыйм Фатих улы (16.04.1900, Казан губернасының Царёвококшайск өязе Иске Өҗем авылы – 03.06.1991, Казан), язучы, тәрҗемәче. Бөек Ватан сугышында катнаша.

1937 елда Казанда Шәрекъ педагогия институтын тәмамлый, 1937–1941 елларда Казан университетында белем ала. 1943–1949 елларда — ТАССР Мәгариф министрлыгында, 1960 елга кадәр «Совет мәктәбе» журналында бүлек мөдире булып эшли.

Беренче хикәяләре 1920 еллар ахырында «Безнең юл», «Мәгариф», «Ярыш», «Башлангыч мәктәп» журналларында басыла башлый. «Тамчылар» (1947), «Шомырт» (1949), «Китап турында китап» (1952) җыентыкларына кергән хикәяләре һәм «Әнисәнең альбомы» (1949), «Канатлы дуслар» (1951) җыентыкларында урын алган шигырьләре мавыктыргыч булулары белән аерылып торалар. Алар балаларда кызыксыну, дөньяны танып белергә омтылу хисләре тәрбиялиләр. А.П.Чеховның «Белолобый» («Акмаңгай», 1932) хикәясен, Е.Ильинаның «Четвёртая высота» («Дүртенче биеклек», 1953) повестен, Б.Полевойның «Мы — советские люди» («Без — совет кешеләре», 1950) хикәяләр җыентыгын, М.Горькийның «Сказки» («Әкиятләр», 1949) җыентыгын, Джек Лондон хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә.

1950 елда Каюм Насыйриның тууына 125 ел тулу уңаеннан «Совет мәктәбе» журналының 1 нче санында дөнья күргән «Каюм Насыйри — педагог» язмасында мәгърифәтче галимнең күпкырлы эшчәнлегенә игътибар юнәлтә, аның татар телен фәнни эшкәртүе, милли грамматика эшләве әһәмиятен, балаларны күздә тотып язган әсәрләрендә гуманизм, тапкырлык, зирәклек һәм кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү омтылышын ассызыклый.

Урта мәктәп өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм методик әсбаплар авторы.

Әсәр.: Каюм Насыйри — педагог (К.Насыйриның тууына 125 ел тулу уңае белән) // Совет мәктәбе. 1950. № 1.

Әд.: Гыйниятуллина А.К. Татар совет язучылары. Казан, 1958.

И.Х.Хәшуллин.

М

МАКСИ́МОВ Кондрат Евдокимович (12.03.1894, Вятка губернасының Уржум өязе (хәзер Киров өлкәсенең Уржум районы) Шишкино авылы – 01.10.1981, Казан), нәкышьче, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1957), ТАССРның халык рәссамы (1960), РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1974).

Казан сынлы сәнгать мәктәбендә укый (1914–1917, бүленеп). 1917–1927 елларда туган авылында сал агызучы булып эшли. 1927–1929 елларда Ленинград рәссамы М.М.Гужавин җитәкчелегендә кабат нәкышь белән шөгыльләнә башлый. 1930–1935 елларда — Казанда сал агызу тәҗрибә станциясендә, сал агызу хезмәтен механикалаштыруны камилләштерү белән шөгыльләнә, уйлап табуга 27 авторлык таныклыгы иясе. Нәкышь сәнгате өлкәсендә актив иҗат эшчәнлеге 1930 еллар уртасында башлана. Бөек Ватан сугышы елларында иҗат мәйданын Татарстан районнарына җәелдереп, миниатюр этюдлар циклын (100 гә якын әсәр), шулар нигезендә тыл хезмәтчәннәренә багышланган «Салларда» (1943), «Урман кисүчеләрнең төн куну урыны», «Орлык фондына ашлык тапшыру» (икесе дә — 1944) күләмле картиналарын яза. 1940 еллар уртасыннан соңрак иҗатында үзәк урын алачак пейзаж жанрына мөрәҗәгать итә. К.Максимовның бай мирасында Кавказ, Кырым, Украина, рус Төньягы пейзажлары да аз түгел, урта рус киңлекләре пейзажы темасы аерым урын били.

Рәссам профессиональ осталыгы, әсәрләрендәге образларның гадилеге һәм ачыклыгы белән иҗатында югары нәтиҗәләргә ирешә. Табигатьне тасвирлаганда кечкенә генә детальләр аша гомуми матурлыкны, дөньяның камиллеген күрсәтеп бирә. Аның пейзажлары әйләнә-тирә дөньяның матурлыгын сурәтләп кенә калмый, авторның табигать белән гармониясен чагылдыра, күңелнең иң нечкә кылларына кагылып изге хисләр тудыра. Татарстанның Идел-Кама киңлекләренә, Вятка урманнарына дан җырлаган «Кама» (1945), «Камага юл» (1953), «Арыш» (1953), «Урманлы офыклар» (1953), «Куйбышев диңгезе» (1957), «Ак мүк түшәлгән нарат урманы» (1965), «Вятка киңлекләре» (1969), «Чыршы урманында көн уртасы» (1973) һ.б. әсәрләре белән рәссам тиңдәшсез пейзаж остасы И.И.Шишкин нигез салган рус реалистик пейзажы традицияләрен дәвам итә, үстерә. К.Максимов әсәрләренең күпчелеге камера-лирик һәм әкияти-романтик характерда: «Абага чәчәк аткан төн» (1946), «Алёнушка», «Кащей патшалыгы» (икесе дә — 1950 еллар), «Тыелган урман» (1959). «Урмандагы янгын», «Урман шаулаган якларда» (икесе дә — 1950 еллар), «Алабуга. 1918 елда кызыл партизаннарны аткан урын» (1967) пейзажларында тирән сагыш чагыла. Рәссам шулай ук таби-


гатьне, күптөрле чәчәкләр һәм җиләк-җимешләр дөньясын тасвирлаучы натюрморт жанрында да уңышлы эшли: «Урман чәчәкләре» (1945), «Чалма чәчәкләр һәм бәллүр» (1946), «Йөзем» (1956), «Шәфталулар» (1965), «Ак карлыган сабагы» (1969) һ.б.

«Каюм Насыйри дару үсемлекләрен өйрәнә» картинасында (киндер, майлы буяу, 1960) рәссам, исеме үк әйтеп торганча, галимнең үләннәрне өйрәнеп утырган мизгелен сурәтли. Бу картина К.Максимовның татар мәдәнияте, әдәбияты, фәне белән таныш һәм, гомумән, рәссамның киң карашлы булуын күрсәтә. Ул татар галименең нинди өлкәләрдә хезмәт куйганын яхшы белә. Төрле предметлар рәвешендә сурәтләнгән образлар аша К.Насыйри шәхесенең киңкырлы булуына



К.Е.Максимов. «Каюм Насыйри дару үсемлекләрен өйрәнә». Киндер, майлы буяу. 1960.

ишарәли. Без картинада галимнең үз кулы белән ясалган глобусны, төрле өлкәләргә караган хезмәтләрен, шулай ук анатомиягә нисбәтле баш сөяге макетын күрәбез. Башка авторлар ижат иткән портрет, бюстлардан аермалы буларак, мәгърифәтче бу әсәрдә кәләпүштән сурәтләнгән, алдында — кызыл башлы сөлге. Төс-кыяфәтендә



К.Е.Максимов

татар зыялыларына хас олпатлык, зирәклек, белем, җылылык чагыла. Картина караңгырак зәңгәр буяулар белән ясалган булса да, аннан ниндидер сихри яктылык сибелә сыман. Өстәлдәге ак кәгазь битләре гүя мәгърифәт нуры чәчә, кулларындагы үләннәр исә бизәк төсмере бирә. Картинаның төп нөсхәсе ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее фондында саклана, күчермәсе К.Насыйриның туган авылы (хәзер Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы) музей-китапханәсендә.

К.Максимов күпсанлы күргәзмәләрдә: республика (1936 елдан); зона — Идел буе рәссамнарының өлкәара күргәзмәсе (Мәскәү, 1943–1945), 6 автономияле республика рәссамнары әсәрләре күргәзмәсе (Мәскәү, 1947), 10 автономияле республика рәссамнары күргәзмәсе (Казан, 1950), «Зур Идел-IV» (Горький, 1974); бөтенроссия — А.И.Куинджи исемендәге җәмгыять әсәрләре күргәзмәсе (Ленинград, 1928, 1929), РСФСР төбәк, автономияле республика һәм өлкәләре рәссамнарының республика күргәзмәсе (Мәскәү, 1949–1951), РСФСР рәссамнары әсәрләре күргәзмәсе (Мәскәү, 1952–1955); бөтенсоюз сәнгать күргәзмәсе (Мәскәү, 1946) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Малмыж (1927), Уржум, Ижевск (икесе дә — 1928), Казан (1940–1981), Мәскәү (1959–2019), Ялта (1964), Яшел Үзән (1973), Чаллы (1981) шәһәрләрендә уза.

Барлыгы 200 гә якын әсәр ижат итә. Аларның күбесе ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чаллы һәм Әл-

мәт шәһәрләре Картина галереяларында, шәхси коллекцияләрдә саклана.

Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнә.

Әсәр.: Не пожалею сил // Мы из Советской Татарии. Казань, 1960.

Әд.: Кондрат Евдокимович Максимов. Выставка произведений художника К.Е.Максимова: 60 лет со дня рождения, 25 лет творческой деятельности. Казань, 1954; Народный художник ТАССР Кондрат Евдокимович Максимов: 75 лет со дня рождения, 40 лет творческой деятельности: Каталог выставки. Казань, 1980; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. Казань, 1984; Голубцова Т.В. Кондрат Евдокимович Максимов. Казань, 2004.

М.Е.Ильина.

МАКСИ́МОВ Николай Валентинович (14.12.1956, Татарстанның Питрәч районы Керәшен Сәрдәсе авылы), тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1991). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2003).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1982), Казанның 90 нчы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1991 елдан Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. 1992 елдан — ТР Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү институтында татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасы мөдире. 1997–2003 еллардан — Казан технология университетында икетеллелек нигезендә белем бирү укыту-методик үзәге директоры. 2007 елдан — Казан университетында.

Хезмәтләре татар телен укыту методикасын өйрәнүгә, урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар теле дәреслекләре һәм уку ярдәмлекләре эшләүгә карый.

Хезм.: Татар теленнән дидактик материаллар: 5–7 сыйныф. Казан, 2000; Татар теле: Урта махсус уку йортлары студентлары өчен дәреслек. Казан, 2005; Урта мәктәптә татар теле: Кушма җөмлә синтаксисы. Казан, 2005; Синтаксиста серләр бар. Башваткычлар. Уеннар. Тестлар. Казан, 2010 (автордаш).

Л.Р.Әскәрова.

МАКСУДИ́ Әхмәтһади (Һади) Низаметдин улы (28.09.1868, Казан губернасының Казан өязе (хәзер Татарстанның Биектау районы) Ташсу авылы – 28.06.1941, Казан), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, журналист, публицист. Татар морзалары Сөендековлар нәселеннән, мулла гаиләсеннән.

1881 елдан Казанда яши. «Касыймия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, шунда укыта башлый. Галимҗан Баруди эшен дәвам итүче буларак, укытуда, беренчеләрдән булып, яңа ысул куллана. 1894 елда Төркиягә китә, анда яңа ысуллы мәдрәсәләрнең укыту тәртипләрен өйрәнә, алдынгы карашлы зыялылар, шул исәптән Әхмәт Мидхәт идеяләре белән таныша. Исмәгыйль Гаспринский чакыруы белән Кырымга килә, андагы «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә шәкертләргә мантыйк фәнен һәм гарәп телен укыта. «Тәрҗеман» газетасында языша. 1896 елда Казанга кайта. Казан татар укытучылар мәктәбенә экстерн тәртибендә имтиханнар тапшырып, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта. 1890 еллар башында бертуган сәүдәгәр-эшмәкәрләр Юнысовларның Мөселман балалар ятимханәсе мәктәбендә, 1 нче шәһәр башлангыч училищесында татар теле, тарих, география укыта. 1903–1905 елларда — Казан университетында ирекле тыңлаучы.

1892 елда иҗекләп укырга өйрәтүче «Мөгаллим әүвәл» («Беренче дә-

реслек») әлифбасын бастырып чыгара, гарәп графикасы нигезендә татарча уку һәм язуны тиз үзләштерү өчен иң яхшы ярдәмлек буларак, бу дәреслек 30 дан артык басма кичерә. Анда эш кораллары, йорт кирәк-ярагы, хайваннар дөньясы, кием-салым, савыт-саба, азык-төлек һәм башкалар турында аерым сүзләр, җөмләләр һәм кыска хикәяләр, татарча ялгызлык исемнәр, антонимнар һәм синонимнар бирелә. «Мөгаллим сани» («Икенче дәреслек» — соңгы баскыч укыту өчен, 1902) — беренче ярдәмлекнең дәвамы, гарәпчә укырга-язарга өйрәтә. 1906 елның августында ул татар мөгаллимнәре җыенында катнаша, анда башлангыч сыйныфлар өчен уртак уку-укыту программасы кабул ителә. 1910 елда Ә.Максуди «Төрки сарыфы» («Татар теле морфологиясе»), «Төрки имля кагыйдәләре» («Татар теленең орфография кагыйдәләре»), «Төрки нәхүе» («Татар теле синтаксисы») дәреслекләрен әзерләп чыгара, грамматика һәм дөрес язу кагыйдәләрен бердәм таләпләр кысасына кертергә омтыла.

Ә.Максуди шулай ук мәдрәсә шәкертләре өчен ислам нигезләрен аңлаткан популяр ярдәмлекләр сериясен эшли. Аның «Гыйбадәте ислам мия» (1898) китабы тулысынча һәм өлешләп күп тапкырлар нәшер ителә. «Русистан. Россия мөселманнары өчен рус телен үзлегеңнән өйрәнү буенча гамәли дәреслек...» (1911), «Французча «Мөгаллим әүвәл» (1913) һәм башка кулланмалар төзеп бастыра. 1898 елда ул «Тәквими дивари» — татарча беренче дивар календарен нәшер итә.

Төркиядә газета чыгару эше һәм «Тәрҗеман» газетасы эшчәнлеге белән танышканнан соң, Ә.Максудида да татар телендә газета нәшер итү фикере туа. 1903–1905 елларда «Йолдыз», «Көндез», «Казан» газеталарын



Ә.Н.Максуди

бастыруга рөхсәт алу өчен берничә омтылыш ясый. 1906 елда «Йолдыз» газетасын ачып, хыялын тормышка ашыра. Әлеге газета революциягә кадәрге татар вакытлы матбугатының иң абруйлы һәм танылган басмаларыннан санала.

Казан шәһәр думасы гласные буларак, Ә.Максуди 1906 елда Казанда беренче татар китапханәсе — «Көтебханәи исламия» ачтыруга ирешә һәм 1923 елга кадәр аңа җитәкчелек итә. Китапханәдә еш файдаланылган басмалар арасында Каюм Насыйри әсәрләре дә була.

Ә.Максуди татар милли-азатлык хәрәкәтендә дә актив катнаша. Энесе Садри Максуди белән, «Иттифакъ әл-мөслимин» мөселман либераль-демократик партиясе лидерлары буларак, аның Үзәк идарәсе составына кертеләләр. Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтаенда (Түбән Новгород, 1906 елның августы) партия Үзәк Комитеты һәм Үзәк Бюросы әгъзасы, Бөтенроссия мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтаенда (Петроград, 1914 елның декабре) Россия мөселман җәмәгать оешмалары Үзәк Комитеты әгъзасы итеп сайлана. Бөтенроссия мөселманнарының беренче (Мәскәү, 1917, май) һәм икенче (Казан, 1917, июль–август) корылтайларында катнаша; икенче корылтайда Милләт Мәҗлесенә депутат итеп сайлана, Милли Идарәнең халык мәгарифе комиссиясе составына кертелә, төркичеләр (Эчке Россия һәм Себер төрки татарларының милли-мәдәни мохтарияты тарафдарлары) фракциясендә тора. Беренче бөтендөнья сугы-

шы (1914–1918) елларында яралыларга һәм сугышта һәлак булганнарның туганнарына ярдәм итү максатыннан мөселман комитеты оештыруда һәм аның эшчәнлегендә катнаша.

Ә.Максуди, Каюм Насыйри кебек, бөтен гомерен татар халкының мәгарифе һәм мәдәниятен үстерүгә багышлый. Ул мәгърифәтче турында истәлек язучы буларак та билгеле. «Шура» журналында (1912) басылган «Габделкаюм Насыйри» мәкаләсендә Русиягә кайткач Каюм Насыйри белән Казанда очрашуны үзенә максат итүе турында яза. 1897 елда ул әлеге теләгенә ирешә һәм Каюм Насыйри белән күрешүен болай дип тасвирлый: «...Печән базарыннан барып Екатерининский урамга кергәч, сул якта бер йортка кердек. Каюм әфәнде Насыйров шул йортның ишегалдындагы флигельдә тора икән. Бик кечкенә агач өй иде. Ишектән кереп бер бүлмәне үткәч, икенче бүлмәдә эстинәгә терәлеп куелган бер өстәл янында камчат бүрекле, бикасап камзуллы бер кеше утыра. Сәлам биреп янына бардык. Күрештек. Язган әсәрләре хакында сүз ачып, хезмәт кылмиясе өчен тәшәккер [рәхмәт] бәян иттек. «Язганыңны укысалар ярар иде, укымыйлар шул», — диде. Каюм әфәнде илә бераз мосахәбәт [кара-каршы сөйләшеп утыру] итәр өчен үтәдән-биредән сүз ачып карадык. Ләкин булмады: сүзне озайтмый, сораган нәрсәгә иң кыска рәвештә бер җавап бирә дә туктый. Ниһаять ядкяр итеп рәсемне сорадык. «Чыгартканым юк», — диде. Бераз утырганнан соң үзе хакында булган хөлус [ихласлык] вә хөрмәтемезне бәян итеп хозурыннан чыктык...». Ә.Максуди әлеге очрашудан күңел күтәрерлек, рух бирерлек бер сүз дә ишетмәвен, ләкин К.Насыйрины күрүенә бик шат булуын, фәкыйрь һәм мескенлек эчендә торып та заманасына, мохитенә күрә шулкадәр зур әдәби, гыйльми хезмәт итә алган мәгърифәтче белән очрашуның күңелендә куәт һәм киләчәккә өмет арттыруын бәян итә.

1933 елда Ә.Максуди, «Бөтенсоюз социал-фашистлар партиясе» оештыруда нахакка гаепләнеп, Вятка шәһәренә сөрелә. 1937 елның гыйнварында аңа Казанга кайтырга рөхсәт бирелә, ләкин 1937 ел ахырында кабат кулга алына. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, 1939 елда төрмәдән чыгарыла.

Хезм.: Габделкаюм Насыйри // Шура. 1912. № 21.

Әд.: Гаффарова Ф.Ю. Әхмәтһади Максуди. Казан, 2002; шул ук. «Йолдыз» кабызган Максуди. Казан, 2006; Зәбиров Г.Г. Максуд баба һәм Максудилар. Казан, 2000; Баттал-Таймас Г.Г. Два брата Максуди: Жизнь, творчество и труды. Казань, 1999; Тазиева Л.К. Лексика букварей Ахметхади Максуди // Бодуэновские чтения. Бодуэн де Куртенэ и современная лингвистика: Междунар. науч. конф. Казань, 2001. Т.2.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МАНСУ́РОВ Роберт Мияссар улы (03.05.1958, Татарстанның Кукмара районы Ятмас-Дусай авылы), мәгариф эшлеклесе, педагог, педагогика фәннәре кандидаты (1998). РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы (1991), РФнең атказанган укытучысы (2002), ТРның мактаулы остазы (2024), ТРның мәгариф отличнигы (2024), ТР Кукмара муниципаль районының мактаулы гражданы (2020). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләгә лауреаты (2024).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, 1984–1985 елларда Кукмараның 3 нче мәктәбендә тарих укыта. 1985–1988 елларда Кукмара районы Ядегәр урта мәктәбе директоры: ул сигезьеллык мәктәпне урта бе-

лем бирүче уку йорты итеп үзгәртә, капиталь төзекләндерү эшләре уздыра, музыка мәктәбе филиалын оештыра, уку йорты районда иң яхшы белем учакларының берсенә әверелә. 1988–2017 елларда Кукмара районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы, 2017–2020 елларда Кукмара районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары — Мәгариф идарәсе башлыгы.

Аның җитәкчелегендә райондагы мәгариф учреждениеләрен, аларның матди-техник базасын, педагогик кадрларны саклап калу һәм үстерү юнәлешендә киң колачлы эшләр башкарыла, уку-укыту һәм тәрбия процессында милли компонент актив гамәлгә кертелә, мәгариф системасы яңарыш кичерә.

2021 елдан Казандагы 80 нче мәктәп директоры (кара: *Сиксәненче мәктәп*). Аның башлангычында мәктәпкә Каюм Насыйри исеме бирелә (2021), проект төзелеп, мәгърифәтченең ике шәкерте арасында утырып торган образы гәүдәләндерелгән «Каюм Насыйри: мәдрәсәдән — дөньяви мәктәпкә» скульптур композициясе эшләнеп, мәктәп эчендәге бер мәйданчыкта урнаштырыла (сынчы Х.Х.Миннегалиев; 2022), мәктәпнең «Каюм Насыйри варислары» гимны языла (Х.Мостафин сүзләре, И.Зарипов көе; 2023), К.Насыйриның интерактив музее оештырыла (2025), галимнең бай фәнни, әдәби һәм педагогик мирасын саклау һәм халыкка, шул исәптән үсеп килүче буынга җиткерү юнәлешендә актив эшчәнлек алып барыла, 2022 елдан «Насыйри укулары» халыкара фәнни-гамәли конференциясе, экология-география конференциясе, Көрәш федерациясенең актив катнашында милли көрәш буенча «Каюм батыр» спорт ярышлары, мәктәп Сабан туе, «БалаSKILS» конкурсы, Бөтендөнья татар конгрессының татар хатын-кызлары «Ак калфак» төбәк иҗтимагый оешмасы белән берлектә «Татар малае — 2022» шәһәр конкурсы уздырыла.



Р.М.Мансуров

Р.Мансуровның җитәкчелек, педагогик һәм методик эшчәнлегенең бай тәжрибәсе махсус вакытлы матбугат басмалары — «Народное образование» (Мәскәү), «Сельская школа» (Мәскәү), «Татарстан», «Мәгариф», «Зечбур» (Удмуртия) журналларында басылып чыккан мәкаләләрдә гомумиләштерелә.

Медальләр, күкрәк билгеләре, Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

И.Х.Хәлиуллин.

МА́СЛОВСКИЙ Пётр Петрович (21.08.1843, Казан — 15.06.1889, Подольск губернасы Каменец-Подольск шәһәре), православие дин эшлеклесе, педагог, миссионер. Казан Богородица хатын-кызлар монастыре рухание гаиләсендә туа; Каюм Насыйри шәкерте.

Казан өяз руханилар училищесында укыганда иске дин тәгълиматы белән таныша. Училищедан соң 1860 елдан укуын Казан руханилар семинариясендә дәвам итә. Семинарияне тәмамлагач, Мәскәү руханилар академиясендә укырга ниятләвен һәм монах булырга теләвен белдереп, үзен Мәскәүгә җибәрүләрен үтенә, әмма гаризасы канәгатьләндерелми; кайбер мәгълүматлар буенча, буйдак булуы сәбәпле Изге Синод аның рухани булуына да рөхсәт бирми.

П.Масловский шуннан соң мөстәкыйль рәвештә миссионерлык эшчәнлегенә әзерләнә башлый, төрле теллэр

өйрәнергә керешә. Ул гарәп, төрек, француз, немец, татар, грек, румын, әрмән, грузин, шулай ук Идел буе халыклары телләрен өйрәнә. Аның татар телен өйрәнүендә Каюм Насыйриның йогынтысы зур була, руханилар училищесында укыганда ул галимнең дәресләренә йөри. Алар арасында дустанә мөгамәлә урнашуы хакында фикер бар. К.В.Харламповичмәгълүматлары буенча, «Масловский үзенең дусты Насыйров әңгәмәләре белән татар теле буенча сыйныфта шөгыльләнүләрен генә тулыландырып калмый, аларны семинарияне тәмамлаганнан соң да дәвам иттерә. Алай гына да түгел, ул Насыйровның әдәби хезмәтләренә кушыла һәм аның татар халык иҗаты ядкәрләре җыентыгын педагогик максатларда эшкәртә... Ул бу хакта сүз йөртеп, аның хезмәтләрен нәшер итү зарурлыгын әйтә: «Бу лекцияләр өчен материал каян алырга?», «Казан губернасы крестьяннары көнкүреше»ндә татарлар кош очышы югарылыгыннан тасвирлана; әмма хезмәт сөюче Насыйровның татар этнографиясе хакындагы язмалары киңрәк һәм ышанычлырак. Аларны нәшер итәргә кирәк иде. Шулай ук Насыйровның «Татарча-русча лөгат»ен дә бастырырга кирәк иде», — ди. Руханинең «Татар телен һәм татарлык фәнен укыту программасы»н гамәлгә ашыру һәм әҗнәбиләр телләрендә миссионерлык журналын чыгару проектлары да уңышсызлыкка очрый. Укытучысы булган Каюм Насыйригача «Таң йолдызы» газетасын татарча чыгарырга рөхсәт алырга ярдәм итәргә тырышып, Масловский ориенталист, миссионер Н.И.Ильминскийга мөрәҗәгать итә, ләкин ул аның үтенечен канәгатьләндерүдән баш тарта. Миссионер газетаның татарларны мәдәни агартудагы ролен бик яхшы аңлап, моңа каршы чыга.

1875 елдан Сембер гимназиясендә рус теле һәм әдәбиятын укыта. 1876 елның мартына кадәр үз курсының «Шигъриятнең кыскача теориясе» («Краткая теория поэзии»), «Шигъри үрнәкләр мисалында шигърият теориясе» («Теория поэзии из разбора поэтических образцов»), «Шигъри үрнәкләрдәге риторика» («Риторика по поэтическим образцам»), «Рус әдәбияты тарихы» («История русской литературы») программаларын яза. 1876–1880 елларда Сембер губернасының халык училищелары инспекторы. 1880 елдан Вятка губернасының Алабуга реаль училищесында француз теле укыта. 1882–1884 елларда Уфа губернасы Минзәлә шәһәре приходы руханиe, 1885 елдан Каменец-Подольск семинариясендә рухани һәм канун укытучысы.

Әд.: Каюм Насыйри. Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык / төз. Р.Ф.Исламов. Казан, 2017; Харламович К.В. П.П.Масловский и его переписка с Н.И.Ильминским (Материалы для истории русской миссии // Известия Общества археологии, истории и этнографии. Казань, 1907. Т.XXIII, вып.1.

И.Х.Хәлиуллин.

МАҺИЯ́РОВА Зилә Миннегаян кызы (01.01.1947, Башкортстан АССРның Чакмагыш районы Яңабирде авылы), педагог, педагогика фәннәре кандидаты (1998). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2012).

Уфа педагогия училищесын (1965), Шадринск педагогия институтын (1976) тәмамлый. 1965–1970 елларда Башкортстанның Эстәрлетамак шәһәрендәге 27 нче балалар бакчасында тәрбияче, 1976–1978 елларда «Юганскнефть» берләшмәсендә балалар оешмалары бүлегенең баш инспекторы булып эшли. 1981 елдан — Татарстан

укытучылар белемен күтәрү институтында мәктәпкәчә укыту һәм тәрбия методисты, 1986 елдан — ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының педагогия училищелары инспекторы, 1991 елдан Казан педагогика институтының педагогика кафедрасында өлкән укытучы, доцент вазифаларын башкара. 2002 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты фәнни хезмәткәре, 2004 елдан — Казан технология университетының ике телдә укыту кафедрасы доценты.

Мәгариф системасы учреждениеләрендә фәннәрне туган телдә укыту методикасын камилләштерү, гаиләдә балаларга татар телен өйрәтү мәсьәләләре З.Маһиярова эшчәнлегендә төп урын били. Ул татар балалар бакчаларында рус телен өйрәтүне кертү өлкәсендә фәнни-практик эшчәнлекне оештыручыларның берсе, шулай ук Казан технология университетында психология, педагогика фәннәрен татар телендә укытуны башлап җибәрүче. Бер үк вакытта галимә «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча зур эш алып бара. Укытучылар, ата-аналар өчен татар телендә «Гаилә һәм мәктәп киңәшмәсе» сериясендә укыту-методик кулланмалар төзеп бастырып чыгара. Галимә шулай ук күренекле мәгърифәтче, педагог К.Насыйри иҗатын өйрәнә, аңа багышланган «Насыйри укулары» фәнни-практик конференцияләрендә катнаша һәм мәгърифәтче әдип турында фәнни хезмәтләр яза.

Хезм.: Каюм Насыйриның Казан «Духовная семинариясе»ндә укыту тәжрибәсенең яңа белем бирүдә әһәмияте» // Вторая Международная научно-практическая конференция «Насыйри укулары» — «Насыровские чтения». Казан, 2023; Родной



З.М.Маһиярова

язык в формировании нравственного поведения младшего школьника. Казань, 2008; Актуальность взглядов Каюма Насыри в ценностной ориентации современной молодежи // Наследие Каюма Насыри в образовательном пространстве на современном этапе: 90-летию со дня рождения татарского просветителя и ученого-энциклопедиста Габделкаюма Насыри посвящается. Казань, 2015; Этнокультурные ценности в педагогическом наследии Каюма Насыри в системе обучения родному языку // Международная научно-практическая конференция X Волковские этнопедагогические чтения «Педагогика любви» (21–23 мая 2015 г.). Абакан, 2015.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕ́К, кара: *Татар мәгърифәтчелеге.*

«МӘҖМӘГУ́ ӘЛ-ӘХБА́Р» («Хәбәрләр җыентыгы»), ислам дине тарихын өйрәтү өчен язылган китап. Каюм Насыйри тарафыннан 1858 елда язылып, 1895 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителгән.

Аның композицион-структур төзелеше өч өлештән гыйбарәт булып, Мөхәммәд пәйгамбәр, аның сәхабәләре, табигыйннар (сәхабәләрне күргән кешеләр) һәм мәшәехләрнең (ишаннар, дин галимнәре) тормышлары, аларның эшчәнлекләре хакында мәгълүмат тупланмасын тәшкил итә. Китапның керешендә язылганча, Каюм Насыйри бу хезмәте өчен төрек язучылары Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия», Чокрыкчызадәнең (Алты бармакның) «Алты бармак китабы»,

борынгы фарсы галиме Әбу Җәгъфәр Мөхәммәд бине Җәрир әт-Табариның «Сират ән-нәби», һәм «Нәтаиҗ әл-фөнун», «Дәр мәҗалис» һ.б. чыганаклардан файдаланган.

2018 елда гамәлдәге татар хәрефләрендә нәшер ителде. карала.


مجمع الأخبار

К.Насыйри. «Мәҗмәгу әл-әхбар». Казан, 1895.

Чыг.: Насыйри К. Мәҗмәгу әл-әхбар. Казан, 1895; шул ук. Мәҗмәгыль әхбар. Пәйгамбәрләребез галәиһиссәлам тормышы. Казан, 2018.

Р.Ф.Исламов.

МӘКА́ЛЬ (гарәп теленнән — مقالة), афористик кыска, сурәтле, грамматик һәм логик яктан төгәлләнгән, оешкан ритмлы, хикмәтле үгет-нәсыйхәтләрдән гыйбарәт фольклор жанры. Ул хикәяләү («Йөргән таш шомарыр, тик яткан таш мүкләнер») һәм киңәш-боерык («Таш белән атканга аш белән ат») характерында булырга мөмкин.

Тел-бизәкләү чарасы буларак мәкальгә төрки шагыйрь Йосыф Баласагуни игътибар итә. «Котадгу белег» («Игелекле белем», 1069–1070) поэмасында ул аны «абышка сүзе» («олылар сүзе») дип атый. Татар әдәбиятында мәкаль «борынгылар сүзе», «ата-баба сүзе», «халык сүзе», «гыйбрәтле сүз» дип тә йөртелә.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, өйрәнүгә һәм бастырып чыгаруга аеруча зур әһәмият бирелә. Ул татар халык *әкиятләрен*, *бәетләрен*, *җырларын*, *сынамышларын*, *табышмакларын*, *риваятьләрен*, *ырымнарын*, *ышануларын* барлау белән бергә, Казан шәһәре, Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендә яшәүче татар халкы арасында йөргән мәкальләрне җыюны мөһим бурычы дип саный. Туплаган мәкальләрен үз әдәби әсәрләрендә һәм уку әсбапларында бастыра. Мәсәлән, 244 мәкале «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)» хезмәтендә урын ала.

Мәкальләрне махсус өйрәнә башлау мәгърифәтче исеме белән бәйле. Күләм ягыннан ин зур саналган «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»ны («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше») К.Насыйри 1879 елда яза башлый. Аның кыскартылган беренче вариантын «Кырык бакча» исеме белән 1880 елда 58 битле китап итеп чыгара. Шуның нигезендә 1882 елда дөнья күргән «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» китабындагы әсәрләрнең күпчелеге көнчыгыш әдәбиятыннан сайлап алып тәрҗемә ителсә дә, К.Насыйри, урынын туры китереп, үз фикерләрен, татар халык авыз иҗатында киң кулланылыш алган дидактик характердагы мәкальләрне өсти. Мәгърифәтче әлеге мәкальләр ярдәмендә үз чорының социаль зарарлы күренешләрен тәнкыйть утына ала. Аларның шактый өлеше үгет-нәсыйхәт һәм сатирик формада бирелгән.

К.Насыйри кулланган мәкальләрнең темасы төрле хасиятләргә, мәсәлән, кеше сыйфатларына («Ач кешенең ачуы яман», «Гакыллы уйлап торганчы, тинтәк эшен бетерер», «Җүләр хатынын мактар, гакыллы атын мактар», «Ул теле белән кыш тота», «Үзе белмәй, кешедән сорамай», «Үзе егылган еламас», «Яхшы хатын арыш онын кәбап итәр, яман хатын богдай онын харап итәр»); көндәлек тормышка («Авызы пешкән өреп эчәр», «Ашап туймаганны ялап туймассың», «Узган болытны тотып булмый», «Урман киексез булмас», «Ит күрмәгәнгә үпкә тансык», «Наданга тик тору җавап»); гаилә-көнкүрешкә («Өеңдәге хәлне күршеңнән сора»), «Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс», «Анадан ала да туа, кола да туа», «Иргә ышанма, Иделгә таянма», «Ир — баш, хатын — муен», «Үксез бозау асраган — авызы борыны май булган, үксез бала асраган — авызы-борыны кан булган») һ.б.га карый.

Әд.: Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: 3 томда. Казан, 1959–1967; Насыйри Г.Г. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 2024: Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан, 1987; Насыров А.К. Образцы народной литературы казанских татар // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Казань, 1896. Т. XIII. Вып. 5.

Р.В.Шәйдуллин.

«МӘНАФИГЫ́ ӘГЪЗА́ ВӘ КАНУНЫ́ СЫЙХХӘ́Т» («Әгъзаларның функциясе һәм сәламәтлек кануннары»), медицина юнәлешендә язылган китап. Каюм Насыйри тарафыннан язылып, 1893 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителгән.

Китапның керешендә үк болай диелә: «Мәгълүм ула ки тыйб дигәнемез адәмнең җисеменә гарыз булган [килеп чыккан] авыруларны белмәктән гыйбарәттер вә һәм ул авыруларны дәва кылып, адәмнең бәдәненнән [гәүдәсеннән] чыкара белмәктән гыйбарәттер. Әмма ул авыруларны бәян кылудан мөкаддәм [элек] җисемнең тәркибен (төзелешен) белмәк тиештер. Ягъни һәрбер әгъзаның әҗзаларын [өлешләрен] вә сыйххәт [сәламәт] хәлендәге вазифаларын белмәк ляземдер [тиештер]».


منافع اعضا
و
قانون صحة

К.Насыйри. «Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт». Казан, 1893.

Хезмәттә һаваның сыйфатлары (эссе, салкын, юеш, коры, саф, бозык), аның кешегә тәэсире; ишетү-күрү һәм алар арасындагы бәйләнеш; исләр һәм аларны сизү тәртибе; баш мие һәм аның биш хис (сизү әгъзалары) аркылы хәбәр алуы; тән әгъзалары һәм аларның эшчәнлеге; ризыклар һәм тукланы ысуллары; хәрәкәтләнү, йоклау һәм башка мәсьәләләр карала.

Чыг.: Насыйри К. Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт. Казан, 1893.

Р.Ф.Исламов.

МӘРҖАНИ́ Шиһабетдин (13.01. 1818, Казан губернасының Казан өязе Ябынчы авылы — 15.04.1889, Казан), илаһият галиме, тарихчы, мәгърифәтче; татар халкының милли историографиясенә нигез салучы галимнәрнең берсе.

Дин әһеле гаиләсендә туа. Башлангыч белемне гаиләдә һәм Ташкичү мәдрәсәсендә (1835) ала. 1838–1849 елларда «Күгелдаш» һәм «Мир-Араб» (Бохара), «Ширдар» (Сәмәрканд) мәдрәсәләрендә укый. Бер үк вакытта абруйлы илаһият галимнәреннән дәресләр ала; китапханәләрдә күренекле гарәп-мөселман фәне һәм әдәбияты вәкилләре һәм башкаларның хезмәтләрен өйрәнә. Урта Азиядә уку чорында Ш.Мәржани борынгы тарихи кулъязмалар, документлар җыю һәм күчерү белән шөгыльләнә, соңрак аларның бер өлеше аның хезмәтләрендә урын ала. Ихтимал, Сәмәркандтагы остазы казый Әбү Сәед карашлары йогынтысында, Мәржанидә дини ислахчылык идеяләре туа. Бохарада ул исламдагы суфичылык агымы белән таныша, Нәкышбәндийә борадәрлегенең өч шәех-остазының шәкерте була, рухани остазлык хокукы — ижазәт алуга ирешә.

Ватанына кайткач (1850), Ш.Мәржани 1 нче Казан мәчетенә имам-хатип һәм мөдәррис итеп билгеләнә. Бер үк вакытта, 1860 елдан, Коръәннең Казан басмалары текстының тулылыгына һәм төгәллегенә күзәтчелек итә. Соңыннан, Россиядә Коръән бастыру тарихына багышланган «Фаваид әл-мөһиммә» («Файдалы һәм мөһим») дигән хезмәт бастыра. 1867–1868 елларда ул Казан ахуны һәм мөхтәсибе була. 1876 елда Ш.Мәржани Казан университеты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* әгъзасы итеп сайлана. 1877 елда IV археология съездында татар галимнәреннән беренче булып Болгар һәм Казан тарихы буенча доклад ясый. Аның фәнни хезмәтләре В.В.*Радлов*, И.Ф.*Готвальд*, А.К.Казимбәк тарафыннан югары бәяләнә. 1880 елда Мәржани Мәскәүгә, Мәккәгә сәфәр чыга, юл уңаеннан Киев, Одесса, Истанбул, Каһирә һәм башка шәһәрләрдә була, күренекле мөселман галимнәре һәм сәясәт эшлеклеләре белән очраша.



Ш.Мәржани

Дини-фәлсәфи хезмәтләрендә һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегендә ислам динен үзгәрүчән чынбарлыкка карата үзенчәлекле яраклаштырырга, татар халкының милли үзаңын формалаштырырга омтыла. Ул мөселман хокук белеме фикъһның кайбер кагыйдәләрен яңадан карап чыгарга кирәклеген әйтә. 1870 елда басылган «Нәзурат әл-хак фи фәдийәт әл-гашаи вә ин ләм йагаб әш-шәфәкъ» («Эңгер-меңгер төшүгә бәйсез рәвештә кичке намазның кирәклеге турында хакыйкатькә бер караш») полемик трактаты зур яңгыраш ала һәм авторга мөселман Шәрегында танылу китерә. Г.Курсави кебек үк, Ш.Мәржани һәр мөселман өчен «иҗтиһад капкаларының ачыклыгы» һәм исламны яңарту идеяләрендә (тәҗдид) нык тора. Исламны бидгатьтән, соңгы яңалыклардан арындырырга, Коръәнгә, Сөннәгә һәм әүвәлге гадел остазларның (сәләфи) гамәлләренә әйләнеп кайтырга өнди. 14 йөз атаклы илаһият галиме әт-Тафтазанининың «Газб әл-фурат вәл-мәгез-золәл ән-нәкыйгли-әсрах-шәрхе әл-Җәләл» («Җәләл шәрехләвен ачыклауга карата бик нык эчәсе килгәндә сусауны басу өчен бирелгән саф һәм татлы су кебек дө-

рес фикерләр», 1875) шәрехләвен тәкъдим итә.

Ислахчылык нәтиҗәсендә Ш.Мәрҗани шикаятьләр һәм мәкаләләрдә төрле хурлауларга, яла ягуларга дучар була. Моңа каршы галим «Хакк әл-мәгърифә вә хөсн әл-идрак» («Хакны тану һәм иң яхшы төшенү», 1880) һәм «Баркил-вәмид фи радд галәл-бәгыйзил-мөсәммә биннәкыйзи» («Тискәре исеме белән аталган дошманнарның фикерләрен кире кагып яндыручы яшен», 1888) исемле яңа китаплар белән җавап бирә; догматик-илаһият һәм фикъһ мәсьәләләре буенча карашларын шулай ук «Хикмәт әл-балигат әл-җәннияти фи шәрх әл-гакаид әл-хәнәфиәти» («Хәнәфиләрнең дини ышанулары турында өлгереп җиткән дөрес карашлар китабы», 1888) хезмәтендә бәянлый, «Хизәмәт әл-хәвәши ли-идәхәт әл-гавәми» («Гаделлекне томалаучы пәрдәне алу өчен шәрехләүләр җыентыгы», 1889) хезмәтендә хәнәфи мәзһәбендәге фикъһ мәсьәләләре тикшерелә.

Ш.Мәрҗани тарих фәнендә тирән эз калдыра. Шундый тарихи хезмәтләренең берсе — 10–12 йөзләр Урта Азия төрки халыклары тарихына багышланган «Гыйрфәт әл-хәвакин ли-ирфәт әл-хәвакин» («Хаканнарны танып белү турында аз-маз гыйлем», 1864). Алты томлы «Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре»; кулъязмада) җыентыгында мәшһүр мөселман эшлеклеләренең тормышы, ислам диненең Идел буе төбәгенә керү тарихы, төбәктә ислам мәдәниятенә зур өлеш керткән аеруча күренекле мөселманнарның эшчәнлеге (икенче том), Россия дәүләтендәге Идел һәм Урал буе мөселманнарының тарихы (алтынчы том) яктыртыла. Шуңа өстәп, Ш.Мәрҗани Мөхәммәд пәйгамбәрнең биографиясен, башлангыч чор ислам тарихын, мөселман илаһияты фәненә күзәтүләр туплаган «Мөкаддимә китаб Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре» китабына кереш», 1883) әсәрен яза.

Ш.Мәрҗанинең икенче тарихи хезмәте — «Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдалы хәбәрләр») әсәрендә гарәп, фарсы һәм төрки чыганаклардан алынган күп кенә нәселләр һәм шәхесләр турында тарихи-биографик белешмәләр, эпиграфика һәм нумизматика мәгълүматлары, телдән әйтелгән хәбәрләр, халык әкиятләре тупланган. Анда беренче тапкыр татар халкы тарихына караган хезмәт иҗат итү омтылышы ясала; «татар» этнонимының законлылыгы нигезләнеп, Идел болгарлары (Алтын Урда һәм Казан ханлыгы буыннары аша) һәм үз чорының Идел-Урал буе татарлары арасында тарихи варислык барлыгын раслана. Идел һәм Урал буе мөселман халыклары арасында җәдитчелек идеяләре үсешенә зур йогынты ясый.

Шул ук вакытта Ш.Мәрҗани татарларның конфессиональ уку системасын заманча яңарту буенча эшләр башлап җибәрә. Ул үзенең мәдрәсәсендә дәресләрне шәкертләрдә мөстәкыйль фикер йөртү сәләтен үстерүне төп максат иткән принциплар буенча алып бара, табигыять фәннәрен, рус телен татар мәктәпләре программаларына кертүне яклап чыга.

Кайбер галимнәр фикеренчә, Ш.Мәрҗани һәм Каюм Насыйри арасында элемтә булган, карашлар төрлелегенә карамастан, алар бер-берсенең яңа чыккан хезмәтләре белән даими танышып барганнар, әмма яшәгән йортлары үзара якын урнашса да, аралашмаганнар, аларның берсе — тарих, икенчесе исә күбрәк тел һәм әдәбият

мәсьәләләренә игътибар биргән. Мөхәммәтхәнәфи *Мозаффар* хатирәләре буенча, Казанда В.В.*Радлов* тәкъдиме белән К.Насыйри тарафыннан 1871 елда татар балалары өчен ачылган башлангыч *рус-татар мәктәбе* нәкъ менә Ш.Мәрҗани мәхәлләсенә караган. Галимнәр бер үк чорда *Казан татар укытучылар мәктәбендә* эшлиләр, К.Насыйри анда татар теле дәресләре алып бара, Ш.Мәрҗани исә, мөселман руханилары вәкилләреннән беренче буларак, 1876 елда дин гыйлемен укытуга керешә. Ләкин аның мәктәп милли зыялыларны әзерләү үзәге булыр дигән өметләре акланмый. Укучылар арасында мәдрәсәдә тәрбияләнүчеләр өстенлек иткән беренче ике елдан соң, мәктәпкә дини белеме булмаган крестьян балалары күпләп кабул ителә башлаган; мәктәпне тәмамлаганнан соң, алар бары тик рус телен генә укыта алганнар. Шул сәбәпле 1884 елда Ш.Мәрҗани мәктәптән китеп бара. Вафатына кадәр фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнә.

Әд.: Мәрҗани. Казан, 1915; Юзеев А.Н. Шихаб ад-дин Марджани — мыслитель, религиозный реформатор, просветитель (к 180-летию со дня рождения). Казань, 1997; Юсупов М.Х. Шигабутдин Марджани. Казань, 2006; Kemper M. Cufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: der Islamische Diskurs unter russischer Herrschaft. B., 1998.

И.Х.Хәлиуллин, Д.А.Шаһавиев.

МӘХМҮДОВ Әмир Гобәйдулла улы (28.06.1947, Башкортстан АССРның Әлшәй районы Әбдрәшит авылы – 15.05.2018, Казан, туган авылында җирләнә), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1999), җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь. Язучылар берлеге әгъзасы (1984).

Башкортстанда Бөре педагогия институтын (1969), Мәскәү өлкә педагогия институтының эстетика кафедрасы каршында аспирантура (1973) тәмамлый. 1974–1981 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1981–1992 елларда Казан педагогия институтында, 1998–2002 елларда ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли. Бер үк вакытта, 1991–1995 елларда, «Суверенитет» газетасы баш мөхәррире һәм ТРның «Суверенитет» комитеты координацион советы рәисе.



Ә.Г.Мәхмүдов

Хезмәтләре 19 гасыр ахыры – 20 йөз башында татар халкының алдынгы эстетик карашларын, Муса Җәлилнең иҗатын һәм идея-эстетик үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Ул шулай ук әдәбият белеме, шул исәптән әдәби тәнкыйть өлкәсендә актив эшли. Аның Муса Җәлил, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Галиәсгар Камал, Каюм Насыйри кебек әдипләр иҗатына багышланган аерым мәкаләләре татар теленнән тыш СССР һәм чит ил халыклары телләрендә дә басылып чыга. Каюм Насыйриның 150 еллыгы уңае белән язылган мәкаләләре төрекмән һәм үзбәк телләрендә дөнья күрә. Автор мәгърифәтче эшчәнлегенең милләткә фидакарьләрчә хезмәт итү үрнәге, китапларының хәзерге милли тормышыбыз өчен дә аваздаш бай хәзинә булуы турында яза. Шигырь җыентыклары авторы.

Муса Җәлилнең 110 еллыгы уңаеннан чыгарылган истәлек медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Матурлык тантанасы: шигырьләр. Казан, 1983; Мәңгелек моң: шигырь-

ләр. Казан, 1987; XIX гасыр ахыры – XX йөз башындагы татар халкының алдынгы эстетик карашлары. Казан, 1998; Эстетический идеал в творчестве Мусы Джалиля. Казань, 1980; Халкың оглы: Каюм Насырының доглан гөнүниң 150 йыллыгына // Эдебият ве сунгат. 1975. 12 февраль; Эзгу туйғулар сохиби: Татар донишманди Каюм Носирийнинг туғилганига 150 йил тўлди // Совет Тожикистинаи. 1975. 14 февраль.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. Казан, 2009. Т. 2; Мостафин Р. Камиллек һәм тирәнлек // Казан утлары. 1981. № 9; Сәхапов Ә. Гүзәллеккә тугрылык // Алтын тамырлар. Казан, 1990; Хисамов Н. Олы гамь белән // Бәрәкәтле чишмәләр. Казан, 1987.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МӘХМҮДОВ Мөхәммәдгали әс-Сөләнгери (1824, Казан губернасының Казан өязе (хәзер Татарстанның Биектау районы) Сөләнгер авылы — 31.01.1891, Казан), рәссам-хаттат, миниатюр китаплар остасы, педагог, статский советник (1870).

Зәңгәр мәчет каршындагы мәдрәсәдә мөдәррис Хәбибулла Рахманкуловта укый (Казан). Камил дәрәҗәдә гарәп каллиграфиясен үзләштерә. А.К.Казимбәк юлламасы белән 1842 елда Казан университетының Шәрекъ бүлегендә һәм Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә гарәп, фарсы һәм төрек-татар каллиграфиясен укытырга рөхсәт ала. Дәресләрендә гарәп язуының классик стильләре — нәсех, тәгълик, шикәстә, дивани, рикъа, рәйхани өйрәтелә (Мәхмүдов һәм аның шәкертләре тарафыннан башкарылган хезмәтләрнең үрнәкләре ТР Дәүләт архивында саклана). 1849 елда крестьян катлавыннан чыгарыла. 1854 елда, Шәрекъ бүлеге Санкт-Петербург университетына күчерелгәндә күчеп китүдән баш тартуы сәбәпле, Казан университетындагы эшеннән азат ителә һәм, каллиграфия укытучысы вазифасы да үзендә калдырылып, Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенә татар теле укытучы итеп күчерелә. Бер үк вакытта, 1846–1848 елларда Казан руханилар академиясендә татар теле укыта, 1850–1854 елларда гимназия каршындагы пансионга назир итеп билгеләнә. 1876 елда яңа ачылган *Казан татар укытучылар мәктәбенең* беренче инспекторы (директоры) булып раслана; шунда ук педагогика һәм дидактика укыта, татарлардан рус теле укытучылары әзерләү системасын булдыруда мөһим роль уйный. Әлеге уку йортын җитәкләгәндә ул чорда шулай ук анда укыткан Каюм Насыйри белән аралаша. 1881 елда ялга китә.

Гарәп графикасындагы кулъязма китапларны күчереп яза, текстларны алдан ук унван — декоратив заставкалар белән бүлә, каймага ала, бүлек исемнәрен төсле, бизәкле үрмә хәрефләр белән аерып куя; еш кына җөмлә азагына нокта урынына чәчәк үрнәкләре ясый. Тушь һәм акварель белән эшли. Шәмаил, кыйтга, хилйә, гарәп язуының сәнгати стиль үрнәкләре авторы (тәгълик, нәсех, шикәстә, дивани һ.б.). Каллиграфия дәресләрендә шәкертләрне язу өчен камыш, шома кәгазь, тушь һәм буяулар белән үзе тәэмин итә.

И.Н.Березин тарафыннан югары бәя алган «Татар телен өйрәнү өчен гамәли кулланма» («Практическое руководство к изучению татарского языка», 1857) авторы; 1870 еллар башында татарларның рус телен өйрәнү проблемаларына мөрәҗәгать итә. В.В.*Радлов* исеме белән басылган «Татар укучылары өчен рус грамматикасы» («Грамматика русского языка, составленная для татар восточной России», 1873) дәреслегенең автордашы; Казан университеты басмаханәсендә Шәрекъ

телләрендә басылган китапларның корректоры була.

Анна тасмасындагы алтын медаль (христиан динендә булмаган затлар өчен 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены тиңдәше) белән бүләкләнә.

Әд.: Дульский П.М. Казанский каллиграф Али Махмудов. Казань, 1930; Зайцев И.В. Казанский каллиграф Мухаммед-Гали Махмудов — Мухаммед-Али б. мулла Махмуд ас-Салангури // Источники и исследования по истории татарского народа. Казань, 2006; Михайлова С.М. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья. Казань, 1972; Траубенберг П.В. Татарская учительская школа в Казани. Казань, 1890; шул ук. Мухамет-Галей Махмудов: Некролог // Казанские вести. 1891.

И.Х.Хәлиуллин.

МӘХМҮТОВ Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы (15.02.1933 Татарстанның Мамадыш районы Түбән Ушма авылы – 17.02.2021, Казан), фольклорчы, филология фәннәре докторы (1996), язучы, шагыйрь. ТАССР һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (1983, 1993), ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1989); Язучылар берлеге әгъзасы (2004).

Казан университетын тәмамлый (1958). 1960–1966 елларда Буа шәһәрендә «Яңа юл» газетасында җаваплы сәркәтип, бүлек мөдире. 1966 елдан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1993 елдан ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшли. 30 елдан артык Татарстан радиосындагы «Тел күрке — сүз» тапшыруының даими авторларының берсе була.

Хезмәтләре татар фольклорының афористик жанрларына карый. Татар фольклоры жанрларының классификациясен (табышмак, мәкаль, әйтем, сынамыш, ант, яхшы теләк, каргыш, ышану, канатлы сүзләр) бирә һәм аларны фәнни яктан тасвирлый. «Татар халык иҗаты» 12 томлык җыентыгын төзүчеләрнең берсе («Табышмаклар» (1977), «Мәзәкләр» (1979), «Мәкаль һәм әйтемнәр» (1987) томнарын төзи, кереш сүз һәм фәнни искәрмәләр яза). Татар халкының йола һәм бәйрәмнәре, 8–17 йөзләр әдәби ядкәрләрендә очраган борынгы төрки афоризмнар турында китаплар, төрки-татар һәм ислам мифологиясенә, татар фольклористикасы тарихына багышланган хезмәтләр авторы.



Х.Ш.Мәхмүтов

Каюм Насыйри хакындагы мәкаләләрендә галимнең халык иҗаты өйрәнүенең мәгърифәтчелек карашлары белән тыгыз бәйләнүе, аның халык авыз иҗаты әсәрләренә эстетик тәрбия чарасы буларак каравы, шулай ук авыз иҗаты җәүһәрләренең танып-белүдәге роленә һәм тарихи эзләнүләрдә файдаланылу мөмкинлегенә зур игътибар бирүе ассызыклана, әлеге ядкәрләрне җыеп-туплап системага салу омтылышы, татар фольклористикасы үсешенә керткән өлеше югары бәяләнә.

Хезм.: Алтын бөртекләр (Каюм Насыйри сүзлекләрендә фольклор әсәрләре) // Казан утлары. 1972. № 3; Энциклопедист галим // Татарстан яшьләре. 1975. 11 февраль; Халык иҗатына мәхәббәт // Социалистик Татарстан. 1975. 13 февраль; «Ел тәүлеге — 12 ай». Казан, 1991; Канатлы сүз — хикмәтле сүз. Казан, 1999; Борынгылар әйткән сүзләр. Казан, 2002; Место Каюма Насыри в истории татарской фольклористики // Выдающийся просвети-

тель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Афористические жанры татарского фольклора. Казань, 1995.

Әд.: Берлекнең яңа әгъзасы: Хуҗи Мәхмүтов / Казан утлары. 2004. № 2; Хисамов Н., Урманче Ф. Җәүһәрче // Фәнни Татарстан. 2002. № 1; Яруллина Л. Гадилектә галилек // Мәйдан. 2003. № 1.

И.Х.Хәлиуллин.

МӘХМҮТОВА Фәүзия Таһир кызы (11.04.1952, Башкортстанның Ярмәкәй районы Иске Сүлле авылы), филолог, педагог, ТРның атказанган укытучысы (2003). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2010).

Башкортстанның Бәләбәй педагогия училищесын (1971), Башкорт педагогия институтының филология бүлеген (1978) тәмамлый. 1978 елда Бәләбәй районы Рассвет мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы, Чакмагыш районы Үрнәк урта мәктәбендә директор урынбасары вазифаларын башкара. 1980 елдан Татарстанның Бөгелмә шәһәре 2 нче интернат мәктәбендә эшли. 1984–1992 елларга Бөгелмә педагогия училищесында укыта. Шул елларда рус мәктәпләрендә татар теле укытучылары әзерләү максатыннан, аның җитәкчелегендә педагогия училищесында беренче татар төркеме оештырыла. 1992–2017 елларда — Бөгелмә районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе башлыгының милли мәсьәләләр буенча урынбасары.

Ф.Мәхмүтовага Бөгелмә шәһәре һәм районы мәгариф идарәсенең милли бүлеген иң җаваплы чорда — Татарстан Республикасында милли хәрәкәтнең киң колач алган елларында җитәкләргә туры килә. Үз вазифаларын төгәл үтәү, рус телле шәһәрдә һәм районда Татарстан Республикасының милли сәясәтен дөрес юнәлештә алып



Ф.Т.Мәхмүтова

бару, татар җәмәгатьчелеге белән дә тыгыз хезмәттәшлек итү югары уңышларга ирешүгә мөмкинчелек бирә. Шушы елларда аның эшчәнлеге татар балаларында ана теленә мәхәббәт тәрбияләүгә, рус телле укучыларга дәүләт телләрен өйрәтүгә, шәһәр һәм районда яшәүче башка милләт балаларына туган телләрен, үз халыклары тарихын, сәнгатен, гореф-гадәтләрен өйрәнү өчен бөтен шартларны да тудыруга юнәлтелә. 1992 елда эшчәнлегенең матур нәтиҗәсе булып Бөгелмә шәһәрендә бердәнбер татар телендә белем бирүче уку йорты — Һади Атласи исемен йөртүче татар гимназиясе ачыла. Әлеге гимназия бүгенге көндә милли белем һәм тәрбия үзәге булып тора, татар мәгарифен үстерүдәге эшчәнлеге өчен Каюм Насыйри премиясе белән бүләкләнә, «Татарстанның иң яхшы 100 мәктәбе» исемлегенә, Россия Федерациясенең иң яхшы белем бирү учреждениеләре милли реестрына кертелә. Бөгелмә шәһәрендә һәм районда татар балалар бакчалары, мәктәпләрдә татар класслары, чуаш, мордва якшәмбе мәктәпләре ачылуда гимназия үрнәге зур роль уйный.

Ф.Мәхмүтова Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медаленә, Һади Атласи исемендәге хәйрия фондының «Фидакарь укытучы» һәм «Мәгърифәтче» бүләкләренә лаек була.

Ф.С.Ғыйниятуллина.

МӘҺДИ́ЕВ Мөхәммәт Сөнгат улы (01.12.1930, Татарстанның Арча районы Гөберчәк авылы – 12.06.1995, Ка-

зан; туган авылында җирлəнə), əдəбият галиме, филология фəннəре кандидаты (1964), язучы. РСФСРның атказанган мəдəният хезмəткəре (1983), ТРның Габдулла Тукай исемендəге Дəүлəт бүləге лауреаты (1990), ТР халык язучысы (1993), Язучылар берлеге əгъзасы (1969).

Арча педагогия училищесын (1947), Казан педагогия институтын (1959) тəмамлый. 1954–1959 елларда Арча районы мəктəпləрендə татар əдəбияты һəм тарих фəннəрен укыта. 1960 елдан Казан университетында, 1963–1991 елларда татар əдəбияты кафедрасы доценты.

Хезмəтləре 1920 еллар башындагы иҗтимагый-мəдəни мохитне, татар халкының рухи мирасын, 1920 еллар татар əдəбиятының күренекле вəкилləрен (Габдрахман Сəгъди, Гали Рəхим, Гомəр Гали, Галимҗан Нигъмəти, Фатих Сəйфи-Казанлы) өйрəнүгə карый. 1967–1970 елларда «Галия» һəм «Буби» мəдрəсələре, татар мəгърифəтчеləре һəм язучылары бертуган Гобəйдулла һəм Габдулла Бубилар, Риза Фəхретдин, Зыя Камали, Галимҗан Баруди, Фатих Кəрими, Фəхреслислам Агиев, Фатих Əмирхан, Мəҗит Гафури, Əхмəтгəрəй Хəсəни һ.б. тормышы һəм иҗаты турында мəкаlələр бастыра.

Əдипнең Каюм Насыйри турында мəкаlələр авторы булуы да мəгълүм. «Наука и религия» журналында дөнья күргəн «Галим Каюм бабай» («Учёный Каюм бабай») мəкаləсендə атаклы мəгърифəтченең күпкырлы эшчəнлеген яктырта, киң катлау вəкилləренə аңлаешлы татар телендə төрле фəннəр (ботаника, география, физика, арифметика, геометрия, физиология, гигиена, агрономия, шулай ук аш-су əзерлəү осталыгы) буенча хезмəтləр, дəреслекləр язуын ассызыклый; аерым алганда, аның фольклорчы сыйфатында татарлардан беренче булып татар халык авыз иҗаты əсəрləрен җыю-туплау белəн шөгыльлəнүен һəм шул ядкəрləрне системалаштыруга алынуын, тел белгече буларак, кырык ел дəвамында татар теле буенча тулы бер фəнни-тикшеренү институты башкарырлык күləмдə хезмəтləр бастыруын, шул исəптəн беренче фəнни грамматиканы, татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген кертеп, төрле сүзлекləр, дөрес язу кагыйдələрен дөньяга чыгарып, җəмəгатьчелеккə җиткерүен, этнограф буларак яңа тикшеренү офыклары ачуын, милли тарихны өйрəнүдə татар халык авыз иҗаты əсəрləреннəн файдалану мөмкинлеген алга сөрүен билгеləп уза; рус шəркыятьче галимнəре Н.Ф.*Катанов*, В.В.*Григорьев*, В.В.*Радлов*, *Гөлнар ханым* (О.С.Лебедева), П.А.*Поляков*, Г.С.*Саблуков* белəн якыннан аралашуы хакында яза; дини вазгыять өстенлек иткəн заманда яшь буынга белем биргəндə рус телендə укытуның нигезен салган мөгаллим булуын ассызыклый.



М.С.Мəһдиев

М.Мəһдиев «Халык иҗаты əсəрləрен системалы итеп тикшерү тəҗрибəсе» (1982, автордаш), «Əдəбият һəм чынбарлык» (1987), «Реализмга таба: 20 йөз башы татар əдəбиятында чынбарлыкның чагылышы мəсьəлələре» (1989) «Талантның социаль тамырлары: яңа революцион күтəрелеш һəм беренче империалистик сугыш еллар татар əдəбияты тарихыннан («Социальные корни таланта: из истории татарской литературы в годы нового революционного подъема и первой империалисти-

ческой войны», 1990) монографияләре авторы.

Ул «Без — кырык беренче ел балалары» (1974) исемле беренче повесте белән үк үзен үзенчәлекле иҗат стиле булган язучы итеп таныта. Аңа лиризм, нечкә юмор, үзенчәлекле тел-бизәкләү чаралары хас. Гадәти булмаган сюжет корылышы, үзәк урынны алып торучы лейтмотивлар әсәрләренең төзелешенә дә үзгәлек бирә. «Кеше китә — җыры кала» (1979) повесте геройлары — авыл кешеләре, вакыйгалар Бөек Ватан сугышы чорында бара. Тылдагы фидакарь хезмәт һәм яу кырындагы батырлыклар, кайгы һәм шатлык, хыянәт һәм ныклык кебек кыйммәтләрне күрсәтеп, автор әсәр геройларының берсеннән төп фикерне әйттерә: «Туган ил өчен мондый авыр вакытларда йомшаклык күрсәтү ярамый, кеше булып, ир булып калырга кирәк. Шул чакта нәсел-нәсәбең, туган җирең, туган авылың да исән-сау булыр». Аның «Фронтовиклар» (1973), «Каз канатлары» (1975), «Мәңгелек яз» (1982) романнары, «Ут чәчәге» (1980) повесте татар әдәбиятында үзенчәлекле урын алып тора.

М.Мәһдиев иҗатында шулай ук «үз» күңел дөньясы гәүдәләнеше сыйфатында үткәннәр тора, язучы һәм аның геройлары гына түгел, халык та үзенә шуннан көч ала, терәк таба. «Торналар төшкән җирдә» (1983) повестенда һәм «Бәхилләшү» (1990) романында үткәннәр мотивына инвариант булып, кешеләрнең бу дөньядан мәңгегә китү, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, көнкүреш детальләренең юкка чыга баруы мотивлары кебек мәңгелек кыйммәтләр тора. Чит илләргә сәяхәте тәэсирендә дөнья күргән «Җир йөзендә алты кыйтга» әсәре (1992) юлъязма жанрында язылган; чит илдәге тормышны үзенеке белән чагыштырып, әдип үз халкының рухи кыйммәтләренең мәгънәсен эзли. Гомеренең соңгы елларында язучы «Ачы тәҗрибә» (1993) исеме куеп мемуарлар яза, ләкин беренче китабын гына чыгарып өлгерә. Аның әсәрләре күп тапкырлар кабаттан басылып чыга, күбесе рус теленә тәрҗемә ителә.

2000 елда Гөберчәк авылында язучының музее ачыла.

Хезм.: Ученый Каюм-бабай: 150 лет со дня рождения татарского просветителя Каюма Насыйри // Наука и религия. 1975. № 2.

Әсәр.: Әсәрләр: 10 том. Казан, 2019–2022.

Әд.: М.Мәһдиев: язучы турында замандашлары. Казан, 2004; Миңнуллин Ф. Яшьлекне сагыну // Балта явызлар кулында. Казан, 1994; Мөхәммәдиев Р. Гадиләр, гадәтиләр // Якутлар табыладыр вакыт белән. Казан, 1983.

Д.Ф.Заһидуллина, И.Х.Хәлиуллин.

МЕДИЦИ́НА (латин теленнән medicina, medicus — табиблык, дәвалау), фән өлкәсе һәм гамәли эшчәнлек, максаты — авыруларны кисәтү һәм дәвалау, кешенең сәламәтлеген нығыту һәм саклау, гомерен озайту. Фән буларак, фундаменталь медицина, биологик медицина, социаль медицина төркемнәрен туплаган фәнни дисциплиналар комплексын тәшкил итә.

Төбәктә табиблык гыйлеме формалашуда Шәрекъ медицинасы, шул исәптән халык медицинасы фәнни юнәлеш алган Идел буе Болгар дәүләте табибларының йогынтысы зур була. Болгар табиблары язган хезмәтләр Шәрекътә дә киң таныла. Алтын Урдада һәм Казан ханлыгында медицина алга таба үсеш кичерә.

Татарлар арасында элек-электән халык медицинасын файдалану мөһим урын били. Медицина буенча татар телендә фәнни эчтәлекле хезмәтләр барлыкка килүнең башлангычы

Каюм Насыйри исеме белән бәйле. Мәгърифәтченең әлеге өлкәдәге китаплары һәм календарьларындагы мәкаләләре фармакологиягә («Хәвасе нәбатат дәваәят ягъни тыйбта мөстәгъмәл нәбатат вә үләннәрнең хасыятене бәян кылур», «Гөлзар вә чәмәнзәр»), анатомия һәм физиологиягә («Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт»), гигиенага («Әхвале бәдән инсан вә хифыз сыйххәт»), сәламәтлек саклау мәсьәләләреңә («Әхвале шәраб әт-дөхан», «Аракы дигән эчемлек адәми зат өчен сарыф бер агудыр», «Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт», «Китап әт-тәрбия», «Чәй бәете», «Томау зәхмәтенә Дубсун дигән табаибның дәвасы», «Күзгә чүп керсә», «Теш авыртканда», «Өч йөз йитмешләп дәва үләннәренең исемнәре русча, латинча, мөселманча», «Тыйбтан берничә сүз», «Чәй-каһвә-себерке» һ.б.) карый.

«Хәвасе нәбатат» әсәре тәүге мәртәбә 1885 елда басылып чыкканнан соң да галим аның өстендә эшләвен дәвам итә, нәтиҗәдә хезмәт соңгы вариантында 1894 елда «Гөлзар вә чәмәнзәр» исеме белән дөнья күрә. Ул татарлар арасында бик популяр була, киң тарала; 1903 елда кабат басыла. Әлеге хезмәттә урын алган тәкъдимнәр арасында акушер-гинекологлар һәм башка һөнәр ияләре өчен файдалы киңәшләр дә бирелә.

К.Насыйриның «Хәвасе нәбатат» хезмәте З.Р.*Шәйхелисламов* тарафыннан әзерләнеп, 1999 елда Казанда кабат нәшер ителә. Ул төзүченең кереш сүзен, ботаника терминнары, үләннең төп үзлекләрен саклау шартлары, тамырлар, үләннәр һәм яфраклар, чәчәкләр, орлыклар һәм җимешләр, кабыклар, кайрылар, бөреләр, үсемлекләрнең организмга тәэсире турында белешмәләр, үсемлекләрнең төркемнәргә бүленеше (тәкъсим нәбатат), кешедә еш очрый торган авыруларга күзәтү урнаштырылган кереш «Мөкаддимә» өлешен, 272 үлән тасвирланып, аларның һәрберсенең шифалы үзлекләре, нинди авыруларга һәм ни рәвешле дару буларак куланылуы бәян ителгән, төп урынны биләгән «Дару үләннәре» бүлеген, 33 төрле авыруга дәва бирүче 76 төрле үлән кушылмасыннан торган тирьякның составы һәм күләме күрсәтелгән «Морәккәб һәм шифалы дарулар» [«Катнаш составлы шифалы дарулар»] бүлеген, «Соңы» («Йомгаклау») бүлекчәсен, өстәмә дару үләннәре сүзлеге, тирьякның (бәлзәмгә, мумиёга охшаган катлаулы дару катнашмасы) составы тасвирланган бүлекчәсен, хәзерге көндә кулланылыштан төшкән үлчәү берәмлекләре исемлеген үз эченә ала (шулай ук кара: *Ботаника*).

Каюм Насыйри «Китап әт-тәрбия», «Әхлак рисаләсе» әсәрләреңә, календарьларында урын алган «Бала тәрбия кылгучы хатынларга нәсыйхәт», «Тәрбия» мәкаләләреңә тәрбия, уку-укыту, акыл, хәтер, әхлаклылык үстерү белән бергә сәламәтлекне нығыту турында да материаллар кертә, шигъри рәвештә язылган һәм 1896 елда брошюра сыйфатында дөнья күргән «Исереклек заманы» әсәрендә, «Әхвале шәраб әт-дөхан», «Аракы дигән эчемлек адәми зат өчен сарыф бер агудыр», «Аракы эчәргә гадәтләнгән кешеләргә бер-ике кәлимә сүз» мәкаләләрендә зарарлы гадәтләрне бәян итә, шулар исәбенә дөрес туклана белмәүне дә өсти. «Иршад әл-әтбихә» китабында өзлексез күп ашарга ярамавын, озак чәйнәргә киреклеген искәртә. «Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт» әсәрендә кеше сәламәтлегенә, тормышына куркыныч янаган нәрсәләрдән (коры һава, һава кинәт эсселәнү, кояш астында озак тору, бозык су һ.б.) кисәтә. «Чәй бәете»ндә лимон белән чәй эчүнең файдасын тасвирлый.

Фәнни хезмәтләр язганда К.Насыйриның ара-тирә тәнәфескә бүленеп, физик күнегүләр ясавы, гомеренең соңгы елларында аякларын җиңелчә паралич сугып, аның әлеге авырудан электр ярдәмендә дәвалануы хакында мәгълүматлар бар. Галим үзенә мөрәҗәгать иткән кешеләргә төрле авырулардан арыну чаралары турында киңәшләр бирә торган булган. Мәсәлән, Зыя *Бәхтияров* К.Насыйри турындагы хатирәсендә: «Мин Казанга килгән саен Габделкаюм абзый янына кереп йөри торган булдым, Аның белмәгән нәрсәсе юк иде. Бигрәк тә мине аның тыйб гыйльмен [медицина] бик күп белүе кызыксындыра иде. Кергән саен мин аннан күбрәк тыйб киңәшләре турында мәгълүмат сорый идем. Аерым авыруларны ничек дәваларга кирәклек турында ул авыл врачлары белмәгән нәрсәләрне белә һәм шул турыда бик яхшы киңәшләр бирә иде. Күбрәк үләннәр белән дәваланырга кирәклек турында сөйли иде», — дип искә ала, бер баруында Үгез Елга (Татарстанның хәзерге Арча районына керә) авылының мулласы Гариф хәзрәткә тап булуы, аның К.Насыйри янына еш килеп йөрүе, килгән саен үз авыруы өчен генә түгел, авылдагы башка кешеләр өчен дә аннан тыйб киңәшләре соравы хакында хәбәр итә.

Мәгърифәтче галим халыкның сәламәтлеген саклау мәсьәләләре белән тирән кызыксынуы һәм заманча рус, гарәп, фарсы телләрендәге медицина әдәбияты белән яхшы таныш булуы, иске хорафатларга, им-том күренешләренә ачыктан-ачык каршы чыгуы, медицина-гигиена белемнәрен таратуы нәтиҗәсендә татар халкы өчен медицина фәне казанышлары белән танышу мөмкинлеге ача һәм шәхси сәламәтлеккә, авыруларга карата җавплы мөнәсәбәт булдыру өчен җирлек тудыра.

Каюм Насыйриның сәламәтлек саклау мәсьәләләренә карашлары А.Р.Еникиева, Ф.Г.Мөхәммәдьяров, Ә.Н.Хәйруллин, Р.М.Шәрәфетдинова хезмәтләрендә яктыртыла.

Чыг.: Насыйри К. Шифалы үләннәр. Хәвасе нәбатат. Казан, 1999.

Әд.: Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык Казан, 2017; Лукина (Еникиева) А.Р. Каюм Насыйри хезмәтләрендә сәламәтлек хасиятләре // Мәгариф. 2008. № 9; Зыятдинов К.Ш., Павлухин Я.Г. Очерки истории медицины Татарстана (до 1917 г.). Казань, 2005; Мухамедьяров Ф.Г. Каюм Насыров как популяризатор медико-санитарных знаний среди татар // Каюм Насыри. 1825–1945: материалы научных сессий, посвященных 120-летию со дня рождения. Казань, 1948; Шарафутдинова Р.М., Хайруллин А.Н. Вопросы народной медицины в этнографических исследованиях К.Насыри // Выдающийся просветитель демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

И.Х.Хәлиуллин.

«МИЛЛИ́ БАЙРА́К», иҗтимагый-сәяси газета. «Ерак Шәрекъ төрки-татар мөселманнарының дини-милли Идел-Урал мәркәзе» органы. 1935 елның 1 ноябреннән 1945 елның август башына кадәр Кытайның Мукден шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 440 саны чыга. Нашире — С.Аити. Оештыручысы һәм беренче мөхәррире — Гаяз *Исхакый*; газетаның исеме Берлинда нәшер ителгән «*Яңа милли юл*» журналы белән аваздаш. Аннан соң мөхәррирләре — И.Дәүләткилдиев һәм аның хатыны Рокыя *Мөхәммәдиш*. Редакциядә М.Арслан, А.Гыйззәтулла, Ш.Илдар эшли; актив авторлар арасында — А.Аги, Х.Болгари, Х.Габдүш, Ф.Гыйльман, К.Салиәхмәт, Х.Сөләев. Татар эшмәкәрләре Ә.Мәңгәр һәм Я.Ибраһим матди ярдәм күрсәтәләр.

Татар эмигрантлары матбугаты арасында газета үзенең басылу дәвамлылыгы, мәкаләләрнең күптөрле булуы һәм укучылар арасында киң таралуы белән аерылып тора, аны Кытайда, Япониядә, Төркиядә, Кореяда, Польшада, Финляндиядә, Германиядә алдыралар. Газета битләрендә Гаяз Исхакыйның татар милләтен, аның мәдәниятен һәм азатлыгын яклап көрәш рухы белән сугарылган уннарча мәкаләләре («Безнең максатлар», «Ерак Шәрекътә милли матбугат», «Милли Мәҗлеснең 20 еллыгы», «Финляндия


ملی بیراق

Far East

بیراق شرقدەگی ایدل–اورال تورک–تاتارلارینگ آطنه

بر تیلیشن.

татарлары», «Советларның руслаштыру сәясәте», «Большевикларның безнең дингә каршы басымы», «Безнең киләчәгебезнең нигезләре» һ.б.) дөнья күрә. Газета мәкаләләрендә татар эмиграциясе тормышы: аның тарихы, иҗтимагый эшчәнлеге, мәдәнияте, әдәбияты, икътисади хәле һәрьяклап яктыртыла.

1937 елның август санында Р.Мөхәммәдишнең «Габделкаюм Насыйри (вафатына 35 ел булу уңае белән)» мәкаләсе басылып чыга; анда автор галимне чит илдә тәрбияләнеп үскән яшь буынга таныту бурычын максат итеп куюын белдерә, аның татар халкын караңгылыктан яктылыкка чыгару ниятe белән озак еллар буе дәреслекләр, календарьлар төзеп бастырып, милли телне гарәп һәм фарсы йогынтыларыннан арындырып, халык сөйләшкән телне алга сөреп, гомере буе фидакарьләрчә халкына хезмәт итүенә басым ясый, күпкырлы фәнни һәм гамәли эшчәнлеген югары бәяли, К.Насыйри тарафыннан ачылган юлда татарларның милли-мәдәни тормышының торган саен киңәя, әдәби телнең байый баруын, шул ук юлда Ш.Мәрҗанинең, Х.Фәезхановның, Акъегетзадәнең дә эшчәнлеген, милли вакытлы матбугатның «Вакыт» һәм «Шура» кебек басмаларының мәйданга килүен горурлык белән ассызыклый.

Әд.: Исхакый Г. Япония — Токио // Мирас. 1995. № 2; Мәхмүт Т. Чит илләрдәге татар вакытлы матбугаты // Казан утлары. 1990. № 10; Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. № 7; Усманова Л. Газета «Милли байрак» — «Энциклопедия» татарской эмиграции // Татарские материалы в Урало-Алтайском архиве Хаттори. Казань, 2016.

И.Х.Хәлиуллин.


«Милли байрак» газетасы.

МИ́НКИН Камил Вәкил улы (17.11.1954, Казан), программист, Каюм Насыйри туганы һәм шәҗәрәсен өйрәнүче галим.

Казан дәүләт университетының механика-математика факультетын тәмамлаганнан соң, 1977–1993 елларда Казан электрон-хисаплау машиналары заводында программист булып эшли. 1993–2010 елларда ТР Эчке эшләр министрлыгында хезмәт куя.

Хезмәтләре Каюм Насыйригa, аның туганнары һәм замандашлары-

на, шулай ук мәгърифәтче турында истәлекләр язучыларга карый. Гомумән алганда, ул галимнең исемен мәңгеләштерү эшендә актив катнаша. К.Насыйриның ир-атлар тармагы буенча хәзерге заманда яшәүче нәселе вәкилләрен ачыклау буенча генеалогик тикшеренү уздыра, бу мәгълүматны ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтына тапшыра. Y–хромосома буенча К.Насыйри ДНКсының гаплотөркемен ачыклау өчен институт хезмәткәрләренә галим нәселенең әлеге вәкилләреннән ген материалларын алуда булышлык күрсәтә. Нәтиҗәдә, К.Насыйриның ДНК




1834 елгы метрика кенәгәсенең нәсел тамгасы куелган бите.

гаплотөркеме ачыклана: N-Y9022> Y23181>Y23183. Бу тикшеренүнең нәтиҗәсе «Татарларның генофонды: тарихи-генетика тикшеренүләре» дигән фәнни хисапта күрсәтелә. К.Насыйри белән шәхси туганлык җепләрен ачыклау буенча генеалогик тикшеренүләр нәтиҗәсендә, К.Минкин һәм К.Насыйриның иң якын уртак буыны — Хөсәен Мукаев, К.Насыйриның әтисе ягыннан бабасы булуы ачыклана. Бу туганлык җепләре ике чылбыр аша сузыла: 1. Камил (1954) — Вәкил (1923) — Кәлимулла (1886) — Мәймүнә — (1855) — Хөснетдин (1804) — Хөсәен Мукаев (1772); 2. Камил (1954) — Вәкил (1923) — Хәдичә (1886) — Нәфисә (1848) — Хөснетдин (1804) — Хөсәен Мукаев (1772).



К.В.Минкин

К.Минкин шулай ук К.Насыйри нәселе тамгасын ачыклау өлкәсендә дә тикшеренүләр үткәрә. Татарларның никахлашу турындагы метрика кәгазьләрендә кияү һәм кәләш ягыннан булган шаһитлар укый-яза белсәләр — үз исемнәрен, укый-яза белмәүчеләр исә тамга — нәсел билгесе куйганнар. Нәсел тамгасы, гадәттә, үзгәрешсез килеш атадан балага күчкән. Архив документларын өйрәнгәндә нәсел тамгасын белү ир-атлар ягыннан туганнарны ачыклау эшен күпкә җиңеләйтә. К.Насыйри нәселе тамгасы Ж хәрефенә охшаш (уртадагы сызыклардан башка). К.Минкин галимнең гарәп телендәге васыятьнамәсен (ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты *Язма мирас үзәгендә* саклана) өйрәнә. Нәтиҗәдә, К.Насыйриның телдән әйтеп



Каюм Насыйри шәҗәрәсенең бер өлеше.

яздырган васыятьнамәсендә күрсәтелгән кеше К.Минкинның ерак бабасы — Әлмән авылы (хәзер Чуаш Республикасы Козловка районына керә) имамы Габделнасыйров (Нигъмәтуллин) Габделкави Насыйр улы булып чыга (искәрмә: бу кеше башка нәселдән, Каюм Насыйриның энесе Габделнасыйр

улы Габделкави түгел): (Камил (1954) — Вәкил (1923) — Хәдичә (1886) — Габделкави (1846). К.Минкин К.Насыйри васыятьнамәсендә үз милке варисларының берсе итеп Габделкави мулла һәм аның хатыны — К.Насыйриның туганнан туган сеңлесе Хөснетдин кызы Нәфисә (К.Минкинның ерак әбисе) күрсәтелүен ачыклый. Русчага нотариус тәрҗемәсендә хата белән — Нәфисә Хәсәнова дип язылганлыгын искәртә. Ул Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендәге Каюм Насыйри кулъязмалары фондын да өйрәнә. Анда сакланучы шәҗәрә буенча К.Минкин ир-атлар ягыннан үз нәселенең үзеннән башланган 11 буынын ачыклый: Камил (1954) — Вәкил (1923) — Кәлимулла (1886) — Вәлиулла (1839) — Фәзлулла (1814) — Минкә (1873) — Уразай (1725) — Әлмөхәммәт (1705) — Ишали (1666) — Байбакты — Ходайберды (Ходайбирде) — Кулсар. Ул шулай ук К.Насыйриның туган авылы Югары Шырдан (хәзер *Кече Шырдан*) тарихы һәм аның кешеләре турында архив материалларын өйрәнә, бу материаллар хәзерге буыннарга әби-бабалары аша нәсел җепләрен барларга ярдәм итә.

Әд.: Генофонд татар: историко-генетическое исследование. Гаплогруппы Y-хромосомы. Казань, 2021.

Ф.Г.Камальтдинова.

МИНҺА́ҖЕВА Гүзәл Юныс кызы (10.12.1963, Татарстанның Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылы), филолог, журналист, ТРның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникация чаралары хезмәткәре.

Казан университетының филология факультетын тәмамлаганнан соң, 1987 елдан Яшел Үзән шәһәренең 12 нче мәктәбендә тарих укыта, 1990–



Г.Ю.Минһаҗева

1993 елларда Яшел Үзәннең 20 нче, 33 нче балалар бакчаларында татар төркемнәре оештыра, татар теленнән белем бирә. 1993–2018 елларда Татмедиа АҖ филиалы — «Яшел Үзән» газетасының җаваплы сәркатибе-баш мөхәррир урынбасары. 2019 елдан «Каюм Насыйри туган җирне торгызу» фонды башкарма директоры урынбасары. *Кече Шырдан* авылында Каюм Насыйри исемендәге музей-китапханә мөдире. Кече Шырданга килгән туристлар өчен К.Насыйри эзләре буйлап экскурсияләр уздыра, музейдагы тарихи экспонатлар белән таныштыра, мәгърифәтченең тормышы, фәнни эшчәнлеге турында лекцияләр укый, яшь буында галим исемен популярлаштыруда актив катнаша. Кече Шырданда мәгърифәтченең туган көненә багышлап ел саен республикакүләм бәйгеләр уздыруда башлап йөрүче.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Ф.Г.Камальтдинова.

МИНҺА́ҖЕВА Ләйлә Ихсан кызы (20.11.1969, Татарстанның Балтач районы Борбаш авылы), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (2011), профессор (2017). РФнең мактаулы мәгариф хезмәткәре (2020). ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге бүләге иясе (2020). Язучылар берлеге әгъзасы (2016). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2010).



Л.И.Миңһаҗева

Казан педагогия институтының филология факультетын (1992) тәмамлаганнан соң, шунда ук татар әдәбияты кафедрасына эшли; 2003 елдан шул кафедра доценты. Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасын тәмамлый. 2011 елдан — Казан федераль университетында, 2017 елдан – татар әдәбияты кафедрасы профессоры.

Хезмәтләре татар балалар әдәбияты, 20 йөз татар әдәбияты, Идел һәм Урал буе әдәбиятлары тарихына, Ибраһим Салахов иҗатына карый. Өч кисәктән торган «Татар балалар әдәбияты» уку әсбабы (автордаш, 2009), югары уку йортлары өчен методик әсбаплар, «Балалар фольклоры» җыентыгы, шулай ук күпсанлы фәнни хезмәтләр һәм тәнкыйть мәкаләләре авторы, «Татар балалары әдәбияты» хрестоматиясен төзүче. Аның чит илләрдә басылган китаплары, мәкаләләре дә татар әдәбиятын дөньякүләм танытуда зур әһәмияткә ия. Россия, Татарстан укытучылары, шулай ук Европа Советы делегациясе, Россия президенты һәм аның ярдәмчеләре алдында ачык дәресләр күрсәткән мөгаллимә. Дөнья күргән хезмәтләрендә балалар әдәбиятына нигез салучылардан булган Каюм Насыйриның тормыш юлы һәм иҗаты югары бәяләнә.

ТР Мәдәният министрлыгының «Мәдәниятттәге казанышлары өчен», РФ Мәгариф һәм министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгеләре белән белән бүләкләнә.

Хезм.: Ибраһим Салахов / Тормышы һәм эшчәнлеге. Казан, 1999; XX гасыр татар балалар әдәбияты: үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре. Казан, 2011; Мең дә бер уй...: чыгышлар, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, иҗат портретлары. Казан, 2015; Каләмендә — балачак галәме / Роберт Миңнуллинның балалар әдәбияты өлкәсендәге эшчәнлеге. Казан, 2018; Татар балалар әдәбияты: белем бирү системасындагы урыны. Югары уку йортлары өчен дәреслек: 3 томда. Казань, 2022; Прошедшие сквозь века... / История развития татарской детской литературы. Germany, 2012; Tatar Çocuk Edebiyatının Tarihi. İstanbul, 2019.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МИҢЛЕКӘЙ (Миңлекәев) Сәхау (Сәхаветдин) Кашафетдин улы (07.12.1895, Самара губернасының Бөгелмә өязе (хәзер Татарстанның Әлмәт районы) Акбаш авылы – 17.01.1954, Башкортстанның Уфа шәһәре), педагог, шагыйрь. Беренче бөтендөнья, Гражданнар, Бөек Ватан сугышларында катнаша.

Бөгелмә өязе Бәйрәкә авылының «Гобәйдия» мәдрәсәсендә (1906–1913), Добрино авылындагы (хәзер Самара өлкәсе Кләүле районында) икееллык рус мәктәбендә (1913–1915) белем ала. 1915 елдан Россия армиясе сафларында. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң полк солдат комитетына, соңрак 12 нче армия мөселман комитетына сайлана. 1918–1919 елларда Акбаш мәктәбендә укытучы, 1919–1921 елларда Бөгелмә шәһәрендә татар балалар бакчалары, балалар йортлары оештыручы һәм аларның мөдире булып эшли. 1932–1942, 1945–1950 елларда Бөгелмә сәүдә-кооперация мәктәбендә эшли, 1950–1954 елларда — Уфа шәһәрендә Башкортстан кулланучылар җәмгыяте укыту курсларында хисап белеме укытучысы.

Мәдрәсәдә укыганда ук тарихи үзгәрешләр чорында татар халкы язмы-

шына, мәхәббәткә, табигатькә багышланган беренче шигырьләрен яза. Соңыннан бу шигырьләр «Солдат моңнары» (1918), «Күңелле шигырьләр» (1921), «Кош-кортлар арасында» (1921), «Кызыл гөлләр» (1923) күмәк шигъри җыентыкларына керә. Балалар өчен дә яза («Балалар өчен җырлы уеннар», 1921; «Җырлы уеннар», 1923; «Тезмә сүзләр», 1931). 1930 елларда иҗаттан читләшә. «Качкыннар», «Гөлгенә» һәм башка поэмалары матбугатта басылмый кала. Фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлеше мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү мәсьәләләренә карый.



С.К.Миңлекәй

Шагыйрьнең мәгърифәтче Каюм Насыйриның вафатына 20 ел тулуга багышлап язылган шигыре дә көчле әхлакый яңгырашка ия: «Кайгыра, яза илендә ни барын, / Күз яшен, үз халкының җыр-моң, зарын, / Халкының күңелендә калган әкиятен, / Такмагын, бар сүзләрен, бар белгәнен. / Дөньясыннан, тормышыннан бизгән ул, / Бар гына гомерен язарга биргән ул. / Халкының наданлыгын, фәкыйрьлеген, / Башкалардан бик күп әүвәл сизгән ул. / Зур сарайлар, таш пулатлар салмаган, / Тәкъва мин, дип, башка чалма салмаган. / Көн вә төн ял итмәгән, тик язган ул. / Кайгыртып: «Халкым надан, халкым надан!» / Язган ул: «Миңа Ходай әмере», — дип, / Халык көлгән: «Каюм ул дәһи... дип». / Нәкъ егерме ел бүген. Үлгән дәһи. / Әй, халык! Торыгыз, олылыйк баш иеп!»

Күргәнебезчә, шигырьдә К.Насыйриның күп әсәрләр иҗат итеп, бай мирас калдыруы, халыкның рухи байлыгын, акыл һәм күңел җәүһәрләрен барлап, бергә туплап, аның үзенә кайтару юлында хезмәт итүе, соңгы көннәренә кадәр белемнәрен камилләштерүе ассызыклана.

Әсәр.: Балалар өчен җырлы уеннар. Бөгелмә, 1921. 1 нче кит.; Балалар өчен җырлы уеннар. Казан, 1925. 2 нче кит.; Шигырьләр һәм поэмалар. Бөгелмә, 1998; Сабанда. Казан, 2001.

Әд.: Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Сәхаветдин Миңлекәй // Мирас. 1995. № 1–2; шул ук. Сәхаветдин Миңлекәй (1895–1954) // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. Казан, 2005; Тукаева Ч. Әтием Сәхаветдин Миңлекәй турында истәлекләрем // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1999. № 3–4.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МИҢНЕГӘ́ЛОВ Хатыйп Йосыф улы (12. 05. 1939, Татарстанның Зәй районы Апач авылы), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы (1991), профессор (1992). ТРның һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе (1994, 2005), ТР Дәүләт бүләге (1995). Кол Гали исемендәге халыкара бүләк (1998), Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге бүләге лауреаты (2005); Язучылар берлеге әгъзасы (1996).

Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый (1964). Сарман районы Теләнче Тамак урта мәктәбендә эшли, Чукмарлы авылы мәктәбендә директор була. 1966 елда КПССның Сарман район комитетына агитация-пропаганда бүлеге мөдире урынбасары итеп күчерелә.

1967 елдан Казан университетының (2010 елдан Казан федераль университеты) татар теле һәм әдәбияты кафедрасында ассистент, өлкән укытучы (1974), доцент (1981), филоло-

гия факультеты деканы урынбасары (1984–1989), татар әдәбияты кафедрасы мөдире (1999–2009) булып эшли. 2022 елдан шул кафедрада профессор-консультант.

Хезмәтләре урта гасырлар һәм 19 йөз татар әдәбиятына багышлана. «Сәйф Сараиның тормышы һәм иҗаты» (1972), «Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты» (1976), «Котб иҗаты» (1976), «Шәрекъ һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар (Поэтика һәм әдәби багланыш мәсьәләләре)» (1988), автордашлыкта әзерләп нәшер ителгән «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» һәм «XIX йөз татар хрестоматияләре» (1982), «Дөньяда сүземез бар...: (мәкаләләр, чыгышлар, юлъязмалар)» (1999), «Гаяз Исхакый мөһаҗирлектә» (1999), «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» (2004), «Гасырлар арасында уйланулар» (2010), «Төрле еллардагы язмалар: (Татар әдәбияты, шигърияте һәм үзара багланышлар» («Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи)» (2010), «Иҗади гамәлле шәхесләр: Мәкаләләр» (2014),), «Төрки-татар, антик һәм рус әдәбияты үсеше этаплары» («Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур») (2014), «VII–XVI йөзләр төрки-татар әдәбиятында дәүләтчелек идеясе» («Идея государственности в тюрко-татарской литературе VII–XVI вв.») (2016), «Әдәбиятара багланышлар җәһәтендә төрки-татар әдәбияты» («Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей») (2017), «Әдәбиятны өйрәнү юлында» (2018), «Озын гомерем хатирәләре. I кисәк. Гомернең беренче чиреге (1967 елның ахырларына кадәр)» (2018), «Бер елда — биш илдә (2018): Биобиблиографик мәгълүматлар = Зарубежные поездки (2018): Биобиблиографические сведения» (2019)



Х.Й.Миңнегулов

хезмәтләре, мәктәпләр һәм гимназияләр өчен дистәләрчә дәреслекләр, хрестоматияләр һәм уку ярдәмлекләре авторы.

Көндәлек матбугатта, фәнни җыентыкларда Каюм Насыйриның тормышы һәм эшчәнлеге турында мәкаләләр бастыра. Галимнең эшчәнлегенә бәя биреп: «Күргәнебезчә, Каюм Насыйри эшчәнлеге гаять күпкырлы. Аның хезмәтләре татар халкын белемле, тәрбияле итүдә үзенә күрә бер мәктәп, университет булды. Татарны татар итеп танытуда, аның милли үзаңын, рухи хәтерен үстерүдә Каюм бабаның эшчәнлеге искиткеч зур. Ул Шәрекъ, рус, Европа казанышларын һәм тәҗрибәсен күрде, алардан иҗади файдалануның матур үрнәкләрен бирде. Әмма К.Насыйри өчен барыннан да элек татарның үз җирлегендә, үзенең рухи мирасына таянып үсүе кыйммәт иде. Шуңа күрә дә ул төп игътибарын татарның телен, тарихын, гореф-гадәтләрен, сүз сәнгатен өйрәнүгә юнәлтте, таралып, сибелеп яткан күп кенә хәзинәләрне замандашларына һәм киләчәк буын укучыларына җиткерде, аларның зиһенен баетты», — дип яза.

ТРның «Фидакарь хезмәт өчен», Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Котб иҗаты: «Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты» курсыннан студентлар өчен уку ярдәмлеге. Казан, 1976; Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. Казан, 1976; Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар (Поэтика һәм әдәби багланышлар мәсьәләсе). Казан, 1988; Ке-

че Шырдан үз улын онытмый // Яшел Үзән. 1997. 25 февраль; Остазыбыз Каюм Насыйри // Фән һәм тел. 1999. № 2; Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан, 2004; Чит илләрдә татар әдәбияты. Казан, 2007; Гасырлар арасында уйланулар. Казан, 2010; Остазыбыз Каюм баба // Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. Казан, 2011; Насыйри // Габдулла Тукай. Энциклопедия. Казан, 2016; Татарская литература и восточная классика: Вопросы взаимосвязей и поэтики. Казань, 1993.

Әд.: Исламов Р. Галим, мөгаллим һәм остаз // Казан утлары. 1999; шул ук. Фән маягы // Мәдәни җомга. 2019. 8, 17 май.

Р.Ф.Исламов.

МИҢНУ́ЛЛИН Җәүдәт Сәлим улы (07. 11. 1953, Татарстанның Кама Тамагы районы Чаллы авылы — 09.10.2019, Казан; туган авылында җирләнә), тарихчы, археограф, тарих фәннәре кандидаты (1988), доцент (1996), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008).

Казан университетының тарих-филология факультетын (1980), шунда ук Совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасы каршындагы аспирантураны (1983) тәмамлый. 1989 елдан Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасы каршында археографик фәнни-тикшеренү лабораториясендә өлкән фәнни хезмәткәр, кафедраның өлкән укытучысы булып эшли. Бер үк вакытта университетның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендәге *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең* Шәрекъ секторы мөдире, баш китапханәче була. 2008–2011 елларда Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе директоры вазифаларын башкара.

Хезмәтләре 19 йөз ахыры – 20 йөз башы татар халкы тарихына, татар



Ж.С.Миңнуллин

иҗтимагый-сәяси эшлеклеләрен һәм иганәчеләрен, чыганакларны өйрәнүгә, историографиягә, текстологиягә, иске татар язуына, Шәрекъ палеографиясенә карый. «Татар палеографиясе нигезләре» (2012), «Текстология нигезләре» (2012), «Иске татар язуы» (автордашлыкта, 2014) уку-укыту әсбапларын, «Шәрык клубы: тарихи очерк» (2013) хезмәтен төзеп нәшер итә. Ризаэтдин Фәхретдиновның фундаменталь «Асар» биобиблиографик хезмәтенең гамәлдәге татар хәрефләрендә бастырылган 3 нче һәм 4 нче берләштерелгән томнарының (2010) фәнни консультанты, ТАССР төзелүгә 100 ел тулу уңае белән 3 томлык «Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгы: Документлар һәм материаллар җыентыгы» («100-летие образования Татарской АССР: Сборник документов и материалов») (2017, 2019, 2020) басмасын төзүче.

Казан университетының СССР тарихы, яңа оештырылган татар халкы тарихы кафедрасы каршындагы махсус археографик экспедиция эшләрендә актив катнаша, 1990 елда аның җитәкчесе була. Шул вакыттагы экпедицияләр Свердловск, Ульяновск, Курган, Түбән Новгород, Пенза, Самара, Оренбург, Киров, Пермь (хәзер край) өлкәләрендәге, Татарстан, Башкортстан, Мари, Чуаш Республикаларының һәм башка төбәкләрнең татарлар күпләп яшәгән 500 артык район-авылларында булып, 3000 берәмлек кулъязма һәм документлар, 1500 гарәп хәрефендәге сирәк китаплар туплап алып кайта.

2010 елдан Татар телен һәм мәдәниятен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча «Җыен» фондының фәнни-популяр «Шәхесләребез» җыентыклар сериясе фәнни мөхәррире була. Әлеге сериядә: «Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык» (2010), «Габдрәшит Ибраһимов: фәнни-биографик җыентык» (2011), «Габдулла Кариев: тарихи-документаль җыентык» (2011), «Әхмәтгәрәй Хәсәни: фәнни-популяр җыентык» (2011), «Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык» (2012), «Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская: әдәби-нәфис, документаль, биографик җыентык» (2012), «Миркасыйм Госманов: тарихи-биографик, фәнни-документаль җыентык» (2014), «Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык» (2014), «Туфан Миңнуллин: фәнни-публицистик, документаль-биографик җыентык» (2015), ике томда «Тукай — ядкярләрдә» (2015), «Бертуган Бикколовлар: әдәби-биографик җыентык» (2016), «Салих Сәйдәшев: фәнни-популяр җыентык» (2017), «Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык» (2017), «Бертуган Хөсәеновлар: Тарихи-документаль җыентык» (2018), «Таҗетдин Ялчыгол: Тарихи-документаль җыентык» (2019) һ.б. дөнья күрә.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар халкы тарихы (XIX–XX йөз башы) курсыннан семинар дәресләр өчен кулланма. Казан, 1995; Иске татар язуы: Уку-укыту әсбабы. Казан, 2012 (автордаш); Татар палеография нигезләре: Уку-укыту әсбабы. Казан, 2012; Текстология нигезләре: Уку-укыту әсбабы. Казан, 2012; Шәрык клубы: тарихи очерк. Казан, 2013; Татарские частные акты XVII — первой половины XIX в.: источниковедческая характеристика. Казань, 2020.


Әд.: Даутов Г. Зыялылык үрнәге (Галим Җәүдәт Миңнуллин истәлегенә) // Мәдәни җомга. 2019. 13 декабрь; Исламов Р. Эзләнүләр дәвам итә // Шәһри Казан. 1997. 1 февраль; шул ук. Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин // Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения. Казань, 2011; шул ук. Күңелемдә якты хатирәсе // Мәдәни җомга. 2019. 22 ноябрь.

Р.Ф.Исламов.

МИҢНУ́ЛЛИН Роберт Мөгаллим улы (01.08.1948, Башкортстанның Илеш районы Нәҗәде авылы – 27.03.2020, Казан), шагыйрь, журналист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1993), Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1998), ТР халык шагыйре (2005), Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге бүләге (1982), Һ.К.Андерсен исемендәге Халыкара мактаулы диплом (1994), ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге бүләге (1997), ТРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге (1998) иясе. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2010).

1966–1968 елларда Илеш районы «Маяк» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң (1973), «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1977–1983 елларда — «Казан утлары» журналында өлкән мөхәррир, соңрак җаваплы сәркәтип, 1983–1986 елларда — Татарстан Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитетында әдәби-нәфис тапшырулар редакция-

се баш мөхәррире. 1986–1995 елларда — «Яшь ленинчы» (1990 елдан «Сабантуй») газетасының баш мөхәррире. Бер үк вакытта «Татарстан» телеканалында «Шигъри тәлгәшләр», «Ихлас», «Китап» тапшыруларын алып бара.



Р.М.Миңнуллин

1990 елдан ТССР, ТР Югары Советы халык депутаты. 1995–2014 елларда ТР Дәүләт Советы депутаты, бер үк вакытта: Мәдәни һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе (1995–2000), ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары (2000–2004), ТР законнары текстларын тәңгәлләштерү комиссиясе рәисе (2004–2009). ТР Балалар фонды (1988–1994) рәисе.

Баштагы чор иҗатында дөньяга, табигатькә яңача карашлы лирик шигырьләре «Идел» альманахында, «Казан утлары» журналында, «Беренче карлыгачлар» (1970), «Безнең бәйрәмнәр» (1974) исемле күмәк җыентыкларда урын ала; аларның герое — шаян-шук фантазёр, кызыксынучан малай. Шагыйрь балалар сөйләменә хас лексиканы, ятышлы гыйбарәләрне бик оста куллана, аларның интонациясен, күңел халәтен ачып бирә («Акбай цирк карый» (1978), «Айга очтык!» (1982) җыентыклары). Күп кенә әсәрләрендә көндәлек мәшәкатьләрне, өлкәннәр белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясын калку сурәтли («Энекәш кирәк миңа» (1990), «Дөньядагы иң зур алма» (1992), «Күчтәнәч» (1995), «Алма бабай» (1997), «Балачакка ешрак кайтыгыз» (2002), «Сөенсеннәр әле сабыйлар» (2002) һәм башка җыентыклары).

Әдипнең иҗаты балалар тематикасы белән генә чикләнми. Аның шигырьләрендә мәхәббәт лирикасы, туган җир белән бәйле әнкәйләр темасы да зур урын алып тора («Бәхетле булыгыз!» (1976), «Мәңгелек сәфәр» (1983), «Әнкәйнең ак чәчләре» (1986), «Сандугачның туган көне» (1990), «Талбишек» (1995), «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» (2002), «Күңелләр нечкәргәндә» (2004) «Татарларым» (2012) — җыентыклары). Миңнуллинның лирикасы тирән фәлсәфәгә корылган, милли мотивлар белән сугарылган. Шигъри теле юмор белән баетылган. Шигырьләре гади, аңлаешлы, төгәл, ачык детальләр хас.

Әсәрләре рус, башкорт, украин, белорус, чуаш, әзәрбайҗан, удмурт, мари, каракалпак, инглиз, поляк, төрек телләренә тәрҗемә ителә.

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, Башкортстан Республикасының «Халыклар дуслыгы» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2004; Әсәрләр: 7 томда. Казан, 2008; Ещё не вечер. Казань, 2008.

Әд.: Урманче Ф. Роберт Миңнуллин: Шигъри осталык серләре. Казан, 2005; Хәзерге татар әдәбияты һәм Роберт Миңнуллин. Казан, 2008; Ар-Серги. В. Путешествие с поэтом Р.Миннуллиным из Казани в Уфу и обратно. Казань, 2008; Сарчин Р. Лирика Роберта Миннуллина. Казань, 2012.

Г.М.Габделхакова, Ф.С.Гыйниятуллина.

МИРХА́ЗОВА Нурзия Рәшит кызы (30.03.1968, Татарстанның Мамадыш районы Түбән Козгынчы авылы), педагог, язучы, шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе. ТРның атказанган укытучысы (2014), ТР Язучылар берлегенең Шәйхи Маннур исемендәге бүләге иясе (2013). Язучылар берлеге әгъзасы

(2017). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2020).

Түбән Кама педагогия училищесын (1987), Чаллы педагогия институтын (2005) тәмамлый. 1987–2002 елларда Түбән Кама шәһәренең 39 нчы «Салават күпере» балалар бакчасында тәрбияче, 2003–2020 елларда өлкән тәрбияче (методист) булып эшли. 2020 елдан Түбән Кама шәһәренең 64 нче «Сөембикә» балалар бакчасы мөдире.

Хезмәтләре һәм эшчәнлеге татар халкының милли гореф-гадәтләрен, йолаларын саклап калуга һәм үстерүгә юнәлтелә. Н.Мирхазова җитәкчелегендә милли юнәлештә эшләүче китапханә хезмәткәрләре, мәктәпкәчә учреждениеләрнең өлкән тәрбиячеләре, башлангыч класс укытучылары катнашында семинар-практикумнар («Каюм Насыйри — бөек галим, педагог», «Туачак көн йолдызы» һ.б.), балалар өчен төрле бәйрәмнәр һәм конкурслар («Без — Тукай варислары», «Минем шәҗәрәм», «Сөмбелә гүзәле», «Сөйкемле бала») уздырыла. Аның «Аналарга мәхәббәт тәрбияләү» (2008), «Минем Ватаным — Татарстан» (2009), «Ана хисе» (2009), «Хыялга канатлар куючы» (2010), «Туган телем — Тукай телем» (2010), «Мин бәхетле гаиләм белән» (2011) методик әсбаплары тәрбия һәм белем бирү өлкәсендә киң кулланыла.

Педагог-шагыйрә балалар психологиясен яхшы белә. Әдәбият-сәнгать алымнары кулланып уздырылган мавыктыргыч дәресләре хыялланырга, ни дә булса эшләргә, уйлап табарга этәрә. Кечкенәләр өчен «Бүләк» (2012), «Уяну» (2015), «Серле рәссам» (2016), «Гөлбакча» (2019), «Бәхет орлыгы» (2022) китаплары дөнья күрә.

Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге каршында эшләп



Н.Р.Мирхазова

килүче «Татар гаиләләре» фонды җитәкчесе, «Мамадыш якташлыгы» җитәкчесе урынбасары, «Ак калфак» татар хатын-кызлар оешмасы вәкиле.

Хезм.: Аналарга мәхәббәт тәрбияләү: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны гаиләдә тәрбияләү үзенчәлекләре. Түбән Кама, 2008; Мин бәхетле гаиләм белән: балалар бакчаларында әхлакый тәрбия бирү буенча методик кулланма. Казан:, 2011; Бүләк: балалар өчен шигырьләр, хикәяләр. Казан, 2012; Серле рәссам — Волшебный художник: шигырьләр. Казан, 2016; Гөлбакча: хикәяләр. Казан, 2019.

Әд.: Минһаҗев С. Тәрбия белән әдәби иҗатны бер күреп // Туган як. 2019. 15 март; Сабиржанов Т. «Мәгариф» авторының «Гөлбакча»лы яңа китабы // Мәгариф. 2019. № 7.

Ф.Г.Камальтдинова.

МИФОЛО́ГИЯ (грек теленнән mýthos — риваять, хикәят һәм logos — сүз, фән), иҗтимагый аң формасы, билгеле бер дини традициягә караган мифлар җыелмасы.

Татар халкының һәм аның ата-бабаларының дөньяга карашларында борынгы заманнардан бирле яхшы һәм яман мифологик персонажлар булган, аларның кайберләре кешеләргә ярдәм иткән, ә кайберләре, киресенчә, аларга зыян китергән. Шул ук вакытта татарлар арасында аларга каршы көрәшү өчен төрле догалар, әфсен-өшкерүләр, үзләрен саклау ысуллары һәм ритуаль гамәлләр кулланырга мөмкин дигән ышанулар да булган. Татар әкиятләрендә, риваятьләрендә һәм халык эпосының башка әсәрләрендә әлеге

мифологик персонажларга ышанулар чагылыш тапкан. Татар халкында борынгыдан килгән мифологик персонажлар арасында: урман иясе — Шүрәле; су ияләре — су анасы, су бабасы, су кызы; йорт һәм абзар-кура ияләре — абзар иясе, өй иясе, бичура; явыз затлар — албасты, аждаһа, дию пәрие, җен, өрәк, убыр, шайтан, юха; шулай ук фольклорда кешеләрне аера торган, Күк дөньясы аллаларына дошманлык кылган, җир асты дөньясы иясе Әрклиг (Орхон-Енисей язма истәлекләрендә аның белән бергә үлем алласы Бүрт хан да искә алына) турында мифологик хикәятләр сакланган.

Татар халкы мифологиясен фән сыйфатында нигезләүгә Каюм Насыйри зур өлеш кертә. Беренчеләрдән булып ул татар халкы авыз иҗаты әсәрләрен, шул исәптән *әкиятләрне*, *сынамышларны*, *ырымнарны*, *ышануларны* өйрәнә һәм туплый башлый. Моның өчен әдип Зөя өязенең Айдар, Бакырчы, Бәчек, Борнаш, Борындык, Кормаш, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Мулла Иле, Норлат, Югары Шырдан (*Кече Шырдан*), Цивильск өязенең Шигали авыллары халкы арасында таралган әкиятләрне, сынамышларны, ырымнарны, ышануларны, мәҗүси йолаларны, әфсен-өшкерүләрне, риваятьләрне һ.б. җыйный һәм бер фәнни калыпка салып берләштерә. Бу җыелган материаллар нигезендә К.Насыйри «Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр», П.А.*Поляков* белән автордашлыкта язылган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» хезмәтләрендә һәм календарьларында бастыра. «Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр» хезмәтенә багышлаган кереш мәкаләсендә Петербург университеты профессоры В.В.*Григорьев*: «Казан университетында алган Европа белеме аны акыл мөнәсәбәтендә шундый югарылыкка күтәргән — ул исламга объектив карый торган безнең мөселманнардан беренчесе... Аның фәнгә охшаш тикшеренүләре мөселман мәгънәсендә пропаганда характерын алу мөмкинлеге турында куркырга бернинди дә сәбәп юк», — дип яза. Өч өлештән торган («Ышанулар», «Сынамышлар», «Мәҗүси йолалар һәм әфсен-өшкерүләр») әлеге хезмәттә татарларның мәҗүсилектән калган йолалары, хорафатлары, галимнең үзе тарафыннан тупланган татар халык әкиятләрендәге уйдырма затлар (су бабасы, су иясе, су анасы, юха, убыр, албасты, өрәк, бичура, өй иясе, абзар иясе, чәчәк анасы, чәчәк иясе, шүрәле, җен, дию пәрие) тасвирлана, әфсен-өшкерүләрдән мисаллар китерелә.

Татар мифологиясе фән буларак 19 йөз ахыры – 20 йөз башында оеша башлый һәм бу процесс нәкъ К.Насыйри исеме белән бәйле. Галим беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗатының мифологик жанрларында сакланып калган шаманизм эзләрен тикшерә, аның тарафыннан әфсен-өшкерүләргә аеруча зур игътибар бирелә. 20 йөз башында аның мифология өлкәсендәге фәнни эзләнүләрен дәвам итүчеләрнең берсе православие миссионеры, ислам гыйлемен өйрәнүче, этнограф Я.Д.*Коблов,* соңрак Н.*Исәнбәт* була. Шулай ук К.Насыйри хезмәтләрендә сурәтләгән кайбер мифологик персонажлар (Су анасы, Шүрәле һ.б.) татар шагыйре Габдулла *Тукай* әкиятләрендә дә урын ала.

Чыг.: Насыйри Г.Г. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 1924; шул ук. Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм го-

реф-гадәтләр // Сайланма әсәрләр. Казан, 1975. Т. 2; шул ук. Поверья и обряды казанских татар // Записки императорского Русского географического общества. 1880. T.VI; Насыров А.К., Поляков П.А. Сказки казанских татар в сопоставлении их со сказками других народов // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1900. T.XVI, вып. 2.

Әд.: Гыйльманов Г. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Казан, 1996–1999. 1–2 нче кит.; Урманче Ф. Татар мифологиясе // Фәнни эзләнүләр юлында. Казан, 2000; Коблов Я.Д. Мифология казанских татар. Казань, 1910.

И.Х.Хәлиуллин.

«МИФТА́Х ӘЛ-КОРЪӘ́Н» («Коръән ачкычы»), Каюм Насыйри тарафыннан Коръәндәге гыйбарәләрнең мәгънәсе һәм тексттагы кулланылышы күрсәтелеп, әлифба тәртибендә төзелгән сүзлек. Хезмәт өчен Коръәннең 1861 елда Казанда нәшер ителгән нөсхәсе файдаланылган. Кирәкле сүрәләр һәм аятьләрне табуны җиңеләйтү өчен К.Насыйри аларның һәрберсен номерлап чыккан (ул вакытта номерлау традициясе булмаган).

Сүзлектә аерым сүзләрнең түгел, ә гыйбарәләрнең тәрҗемәсе бирелгән. Анда барлыгы 46200 гыйбарә теркәлгән һәм аларның кайсы сүрәдән булуы күрсәтелгән. Сүзлек 28 бүлектән (бабтан) һәм 160 бүлекчәдән гыйбарәт. Бу хезмәт немец галиме Густав Флюгель тарафыннан — 1842 елда, Россия Император университеты профессоры А.К.Казимбәк (Мирза Казимбәк) тарафыннан 1859 елда төзелгән сүзлекләрдән үзенең җиңел аңлашлы булуы белән аерылып тора һәм ислам дөньясында Коръәннең беренче конкорданс сүзлеген тәшкил итә. Сүзлек 1886 елда кулъязма хәлендә тәмам ителгән һәм К.Насыйри үзе аны «Иҗтиһадымның [тырышлыгымның] иң олысы» дип бәяләгән.

Сүзлекнең кулъязма нөсхәсе хәзерге вакытта Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә* саклана. Аның белән үз вакытында танышкан әдәбият галиме һәм язучы Мөхәммәт *Гали* болай дип яза: «Басылмаган оригиналь кулъязма китаплар арасында иң зурысы — Коръән аятьләрен эзләп табу турында, зур форматта 212 битле «Мифтахел фөркан» исемендә зур әсәр. Насыйриның бу китабы хәзерге көн өчен үзенең әһәмиятен җуйган булса да, ләкин аның төзелү системасыннан әле хәзер дә файдаланырга мөмкин. Чөнки аның бу китабы буенча Коръәндәге 6000 нән артык аять яки бәетне һәм шул бәетләргә кергән аерым сүзләрне бик ансатлык белән эзләп табарга була. Безгә киләчәктә Насыйриның шушы китабында күрсәтелгән систему буенча Г.Тукай яки М.Гафури кебек шагыйрьләрнең тулы җыентыкларына кергән аерым куплет, строфа яки аерым юл шигырьләрне һәм алардагы сүзләрне эзләп табу өчен бик яхшы кулланма төзергә мөмкин булачак».

К.Насыйриның 130 ел билгесезлектә яткан әлеге хезмәте ислам белгече, философия фәннәре кандидаты Айдар *Хәйретдинов* тарафыннан кулъязма текстның гамәлдәге татар графикасында транслитерациясе, тәрҗемәсе эшләнеп (филология фәннәре кандидаты Ф.*Шәфигуллина* белән автордашлыкта) 2015 елда Казанда факсимиле рәвешендә 2 том итеп нәшер ителә.

Чыг.: Насыйри К. Мифтах әл-Коръән: Коръән сүзләренең әлифба тәртибендәге тулы сүзлеге / фәнни мөх. А.Г. Хәйретди-

нов, әдәби мөх. Р.Ф.Шәфигуллина. Казан, 2015.

Әд.: Гали М. Каюм Насыйриның кулъязма мирасы // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Sibgatullina E.T. Kelâm Şerif (faksimile Kur'an metni); Miftâhu'l-Kur'ân, Kayyûm Nâsırî, hazırl. A. G. Hayretdinov — R. F. Şafigullına, I-II, Kazan: Poznaniye Neşriyatı, 2015 // İslâm Araştırmaları Dergisi. 2016.

Р.Ф.Исламов.

МИХА́ЙЛОВА Сәвия Мөхәммәтдин кызы (21.09.1942, Татарстанның Саба районы Туктамыш авылы – 01.03.2007, Казан), тарихчы, тарих фәннәре докторы (1986), профессор (1989), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1991).

Казан университетының тарих-филология факультетын (1965), шунда ук КПСС тарихы кафедрасында аспирантура (1968) тәмамлый. Бер үк вакытта, 1965–1969 елларда, Казандагы 118 урта белем бирү мәктәбендә тарих укыта. 1969–2007 елларда Казан университетында: 1975 елдан — доцент, 1994 елдан — сәяси тарих кафедрасы мөдире. Бер үк вакытта, 1990 елдан, Казан техник университеты каршындагы Укытучыларның белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү институтында тарих кафедрасы мөдире.

Хезмәтләре Казан университеты тарихына һәм аның Идел буе, Урал алды халыкларының белемен һәм мәдәниятен үстерүдәге әһәмиятен билгеләүгә, шәркыять белеменә, хәзерге заман милли мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә һәм милли мәдәниятләрнең үзара йогынтысына карый. «Культурология» уку ярдәмлеге авторларының берсе (1998).

1976 елда нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган



С.М.Михайлова

«Каюм Насыйри һәм Казан университетында шәркыятьчелек белеме» мәкаләсендә галимнең Казан шәркыятьчелек белеменең иң яхшы традицияләрен үзләштереп, үзенең фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә беренчел чыганакларны әтрафлы анализлау, фәнни объективлык, мәдәният үсешендә өйрәнелүче халыкның ролен күрсәтү принципларына таянуы, Н.И.Лобачевский, Н.И.Симонов, А.М.Бутлеров, А.П.Щапов, П.Лесгафт идеяләре йогынтысын кичерүе, тарих, этнография өлкәләренә тирән әзерлекле хәлдә керүе, Н.М.Карамзин, Н.Г.Устрялов, С.М.Соловьёв һәм В.О.Ключевский хезмәтләре, «Современник», «Отечественные записки» журналлары белән таныш булуы яктыртыла, аның Казан һәм Петербург шәркыятьче галимнәре белән дустанә һәм эшлекле мөнәсәбәтләрдә хезмәттәшлек итүе, аны мәгърифәтченең алдынгы карашлары белән килешмәгән, әмма шәркыятьчелек фәненең күренекле вәкилләре буларак абруй казанган белгечләрнең дә (В.В.*Григорьев*, Н.И.Ильминский) тануы, чит илләрдә дә белүләре (хезмәтләренә Г.Балинт, И.Тюзел, Х.Вамбери кебек танылган галимнәрнең сылтама ясаулары) ассызыклана.

Медаль, ТРның Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Хезм.: Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья (1800–1861). Казань, 1972; Каюм Насыри и востоковедение в Казанском университете // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Казанский университет и просвещение народов Поволжья

и Приуралья (XIX в.). Казань, 1979; Казанский университет в духовной культуре народов востока России (XIX в.). Казань, 1991; Культура многонациональной провинции: Поволжье и Приуралье. Казань, 2001 (автордаш).

Әд.: Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Библиографический словарь. Казань, 1999; Тюркологи современного Татарстана: Справочник М., 1997.

И.Х.Хәлиуллин.

МИЯССА́РОВА Илсөяр Хәбибулла кызы (01.12.1950, Татарстанның Тәтеш районы Кече Әтрәч авылы), педагог, ТРның атказанган укытучысы (2006), РФнең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2012). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2010).

ТАССРның Апас районы Иске Йомралы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң (1968), комсомол юлламасы буенча Алабуга педагогия институты каршында оештырылган педагогик курсларда белем ала. Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлый (1978). 1969–1971 елларда Тәтеш районы Олы Тормы сигезьеллык мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы, 1971–1975 елларда Тәтеш районы Зур Әтрәч урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 1975–1992 елларда Казан шәһәренең 26 нчы һәм 89 нчы мәктәпләрендә татар теле укытучысы булып эшли. 1992–1996, 2005–2016 елларда Казан педагогия көллиятендә татар теле һәм әдәбияты, төрек теле укыта. 1996–2005 елларда Татар гуманитар педагогия институты укытучысы.

Эшчәнлеге татар әдәбияты һәм теле буенча уку әсбаплары, дәреслекләр, башлангыч мәктәп өчен укыту-методик ярдәмлекләр әзерләүгә карый. Өч кисәктән торган «Татар балалар әдәбияты» уку әсбабы авторы (автордаш, 2009). Әлеге хезмәттә балалар әдәбияты турында тулы мәгълүмат бирелә, алар мисаллар белән ныгытыла; балалар әдәбиятының барлыкка килү тарихы, үсеш перспективалары күрсәтелә. Уку әсбабы белән бергә, ике кисәктән торган хрестоматия дә төзелә.



И.Х.Мияссарова

И.Мияссарова озак еллар дәвамында студентларга Каюм Насыйри иҗаты, тормышы һәм эшчәнлеге турында төпле белем бирә. Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан һәм башка күренекле әдипләр иҗаты белән таныштырганда, аларның мәгърифәтче К.Насыйрины яратып укулары, аннан күп нәрсәләргә өйрәнүләре, ул салган сукмактан атларга омтылуларын ассызыклый. Аның җитәкчелегендә мәгърифәтче әдипнең тәрбия мәсьәләләрен якты рткан, балаларда кече яшьтән формалаштырылырга тиеш гүзәл сыйфатларны үзәккә алган «Әхлак рисаләсе», «Тәрбия», «Китап-әт-тәрбия» һәм башка хезмәтләре буенча проектлар яклана, әдәби һәм гыйльми эшчәнлегенә багышланган курс һәм диплом эшләре языла. И.Мияссарова даими рәвештә К.Насыйри музеена экскурсияләр оештыра, аңа багышланган әдәби кичәләр, конференцияләр уздыра, аның тарихтагы эзен, зурлыгын һәм бөеклеген аңлату өчен, студентлар һәм мәктәп укучылары белән туктаусыз эш алып барыла.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бү-

ләкләнә, «Мәгарифтә ирешкән уңышлары өчен» күкрәк билгесе иясе.

Хезм.: Татар балалар әдәбияты: Гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы: 3 томда. Казан, 2003 (автордаш); Татар теле: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, 2011 (автордаш); Әдәби уку. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). Казан, 2017.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МОЗАФФА́Р Мөхәммәткамал (?–?), Каюм Насыйри турында истәлек язучы. Аның хатирәсе беренче мәртәбә «Шура» журналында (1912) дөнья күрә.

Үзенең истәлегендә 1896 елда мәгърифәтче К.Насыйри белән Казанга килгәч очрашулары турында яза. Автор, аның янына барып, озак итеп сөйләшеп утыруларын, сөйләгән сүзләрен дәфтәренә теркәп баруын искәртә. Ләкин билгеле бер вакыйгага бәйле рәвештә бу дәфтәр аннан алына һәм кире кайтарылмый. Шул сәбәпле ул үзенең истәлегендә әлеге очрашуны, әлеге язмага нигезләнеп, җентекле тасвирлау мөмкинлеге булмавын әйтә. Аның хәтерендә калганы исә икесе арасында кояшның нуры кими бару һәм эсселеге сүнү хакындагы әңгәмә була. Бу турыда ул К.Насыйриның түбәндәге сүзләрен китерә: «...безнең әбиләр урак өстендә юлдагы тузанга күмелгән тавык йомыркасының ашарлык дәрәҗәдә булып пешүене сөйлиләр иде. Имди хәзерендә эсселек ул дәрәҗәләргә йитми, бу сүзне берва-кыт фән галимнәре дә раслау кылырга тиешле. Электрик яктысы вә көче һәм дә һәрбер ут әсбабы кояштан алынуы дөрес булырга тиешле». Автор, бу мәсьәләдә үз тәҗрибәсе һәм мәгълүматы булмау сәбәпле, күбрәк К.Насыйриның сүзләрен игътибар белән тыңлап утыруын искә ала.

Истәлек язучы үзенең хатирәсендә «К.Насыйриның өстендә бикасап тышлы кыскарак тун, аягында бәйләнгән ак оек» булуын, «диварында асып куйган ике сан шәһадәтнамә, язулар» барлыгын игътибар үзәгенә ала. Бу язуларның дарелфөнүн (Казан университеты) идарәсе тарафыннан бирелгәнлеген, К.Насыйриның үзе дарелфөнүндә хезмәттә вакытында анда китапларның ифрат дәрәҗәдә күп булуы, «кулында ике сан мәктүб (хат), бер сан китаплары хакында хисап» язуын һәм шуларны идарәгә җибәрүе турында сөйләвен әйтеп үтә. Шулай ук кара: *Истәлекләр.*

Хезм.: Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. № 23; Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1913. № 6; Габделкаюм әфәнде Насыйри хакында // Әдәби мирас. Казан, 1996. 3 кит.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МОЗАФФА́Р Мөхәммәтхәнәфи (?–?), Каюм Насыйри турында истәлек авторы. Аның хатирәсе тәүге мәртәбә «Шура» журналында (1913) дөнья күрә. Аннан соң әдәбият галимәсе Фатыйма *Ибраһимова* тарафыннан «Әдәби мирас»ның 3 нче китабында нәшер ителә.

Мөхәммәтхәнәфи әлеге истәлекне әтисе Мөхәммәджан Мозаффар сөйләгәннәрдән аның рөхсәте белән язып ала. Әтисенең мәгърифәтче белән мәдрәсәдә шәкерт вакытында күрешүен, К.Насыйриның, русча укырга кызыгып, яшерен укыштыра башлавын искә ала. Аңа Кәрим хәзрәт рус телен өйрәнергә рөхсәт итмәсә дә, К.Насыйриның русча укудан туктамаганы мәгълүм була. Авторның әтисе дә мәгърифәтче галимнән русча дәресләр алу-

ын һәм К.Насыйриның күп кенә язмаларын үзенә күчерүен ассызыклый. Янгын вакытында галимнең кулъязмалары юкка чыккач, күчереп алынган «Әмсале Коръән», «Әмсале хәдия», «Хикәят вә ләтаиф», «Төрек вә татар тарихы» дигән 44 бит язманы аңа яңадан бирүен хәбәр итә.

Автор үзенең истәлегендә К.Насыйриның татар телен тирәнтен өйрәнгән һәм аны үстерүгә күп көч куйган, грамматикасына нигез салган тел галиме булуын ассызыклый. Хатирәдә мәгърифәтче галимнең: «...Адәм баласы тел үзрә туган булса, ул үзенең туган телен кагыйдәсез дә белер вә һич яңлыш тәләффыз [сөйләү] кылмас, хата сөйләшмәс. Ләкин гайре телне үгрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кавагыйден [кагыйдәләр] белмәк зарурдыр. Чөнки кеше үз телен яхшылап белмәсә, гайре телгә төшенә алмас» дигән сүзләре китерелә. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Чыг.: Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Шура. 1913. № 6; Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Әдәби мирас. Өченче кит., 1996.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МО́КРЫЙ УРАМЫ́, Казандагы тарихи урам. 1646 елдан мәгълүм. Шәһәрнең көньяк өлешендә урнашкан. Хәзер Вахитов районына керә. Ташаяк урамыннан Рөстәм Яхин урамына кадәр 0,5 км озынлыкта сузыла.



Мокрый урамындагы Соболев номерлары. XX йөз башы.

1872 елда Мокрый урамындагы кабакның икенче катында урнашкан фатирны түләү тәртибендә вакытлыча файдалануга алып, Каюм Насыйри анда татар балалары өчен шәһәрдә беренче *рус-татар мәктәбе* ача. Заман дашларының хатирәләренә караганда, мәктәп анда нибары ике ай дәвамында эшли, әләкләр аркасында һәм башка сәбәпләр белән (ишегалдында сыра заводы эшләп тору, сәрхушлык таралу һ.б.) ябылырга мәҗбүр була.

Әд.: Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре. Казан, 1995; Казань: исторические районы, слободы, улицы, площади и парки: иллюстрированный энциклопедический справочник. Казань, 2021. Кн. 1; Клочков А.И. Казань: логовища мокрых улиц. Казань, 2019; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. Казань, 1993.

И.Х.Хәлиуллин.

МОСТА́ФИН Рафаэль Әхмәт улы (14.05.1931, Татарстанның Баулы районы Баулы посёлогы – 14.04.2011, Казан), әдәбият белгече, тәнкыйтьче, язучы, публицист, филология фәннәре кандидаты (1971). ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985), Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге бүләге (1976), ТРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге (2006) лауреаты. Язучылар берлеге әгъзасы (1962).

1954 елда — Казан университетының тарих-филология факультетын, 1960 елда шунда ук татар әдәбияты кафедрасында аспирантура тәмамлый. Удмурт АССРның Воткинск район газетасы хезмәткәре, Баулыдагы 1 нче урта мәктәп укытучысы, комсомолның Баулы район комитеты секретаре, «Литература и жизнь» газетасы-

ның үз хәбәрчесе була. 1961–1963 елларда — Казан телевидение студиясенең әдәбият-сәнгать программалары баш мөхәррире, 1963–1965 елларда — Татарстан Язучылар берлеге җаваплы секретаре,



Р.Ә.Мостафин

1965–1969 елларда — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире. 1978–1991 елларда Казан университетында укыта. 1991–1997 елларда «Татарстан» журналы баш мөхәррире, 1997–2001 елларда «Казанские ведомости» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, 2001–2014 елларда «Татарстан» журналы баш мөхәррименең беренче урынбасары һәм әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Хезмәтләре хәзерге татар әдәбиятына, милли әдәбиятларның үзара баетылу мәсьәләләренә, татар әдипләренә, әдәби тәрҗемәгә, Казан тарихына, сәяси репрессияләргә багышлана. Галимнең иҗатында татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең тормышына һәм иҗатына багышланган әсәрләр аерым урын алып тора («Эзләнү дәвам итә» (1965, автордаш), «Герой шагыйрь эзләреннән» (1971), «Өзелгән җыр эзеннән» (1974), «Муса Җәлил» (1986) һ.б.). Р.Мостафин әсәрләре һәм фәнни эзләнүләре белән Муса Җәлилнең исемен аклауга һәм мәңгеләштерүгә зур өлеш кертә.

«Кызыл таң» газетасының (Уфа шәһәре) 1975 елгы 14 февраль санында Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулуга багышлап басылган «Мирас итеп калдырган» мәкаләсендә галимнең төрле фәннәр, мәдәният, әдәби тәрҗемә өлкәләрендәге эшчәнлеге, шәркыятьче рус галимнәренең аның хезмәтләрен югары бәяләүләре һәм шәхесен тирән ихтирам итүләре яктыртыла, әсәрләрен (гомуми күләмдә 500 ләп табак 40 лап хезмәтне) аңлаешлы тел белән язуы һәм милли телне эшкәртүе нәтиҗәсендә «җанлы татар теленә гражданлык хокукы бирүе»нә басым ясала.

«Почёт билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Әсәр.: Мирас итеп калдырган: Каюм Насыйриның тууына — 150 ел // Кызыл таң. 1975. 14 февраль; Кабан күле серләре. Казан, 1990; Казань и её слободы. Казань, 2001 (автордаш); О времени, о жизни, о себе. Казань, 2002; Силуэты: Литературные портреты писателей Татарстана. Казань, 2006.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. Казань, 2009. Т. 2.

И.Х.Хәлиуллин.

«МОХТӘСА́Р ТӘВАРИ́Х ӘНБИЯ́...» («Мохтәсар тәварих әнбия галәйһем әс-сәлам» — «Пәйгамбәрләрнең кыскача тарихлары»), балалар өчен башлангыч уку китабы. Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1884 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә. Әлеге хезмәтне язганда ул 15–16 йөз төрек галимнәре Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия», Нишанҗызадә бине Әхмәд бине Мөхәммәд бине Рамазанның «Мират әл-каинәт», борынгы фарсы галиме Әбу Җәгъфәр Мөхәммәд бине Җәрир әт-Табариның «Табари тарихы» әсәрләрен файдалана.

Аллаһы тарафыннан җирнең яратылуы, Адәмнән башлап пәйгамбәрләрнең тарихы, аларның могҗизалары; Адәм белән Һауаның Җәннәттән куылгач, җирдә тормыш итүләре, аларның балалары; шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәр, аның сәхабәләре турында мәгълүмат китапның эчтәлеген тәшкил итә.

Китап кабат 1898 елда Казан университеты матбагасында бастырыла.

Чыг.: Насыйри К. Мохтәсар тәварих әнбия... Казан, 1884.

Әд.: Катанов Н. Мухтасар-и тауарих-и амбия (Краткие биографии пророков). Казань, 1899. Типо-литогр. ун-та. 79 стр. // Деятель. 1900. № 2.

Р.Ф.Исламов.

МӨХӘММӘДИ́Ш Рокыя Сабиржан кызы (1908, Казан губернасының Тәтеш өязе Үтәмеш авылы — 1989, Казан), педагог, публицист, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе; Ерак Көнчыгыш төрки-татарларының милли хәрәкәте активисты. Төркиянең Истанбул шәһәрендә яшәүче Мәрмәрә университеты профессоры, тарих фәннәре докторы Надир Дәүләтнең (1944–2021) әнисе.

1911 елдан — Иркутск, 1916 елда — Хабаровск, 1916 елдан — Благовещенск, 1918 елда — кабат Хабаровск, 1919 елдан — Уссурийск (шунда гимназия тәмамлый), 1925 елдан – Харбин (Кытай), 1927 елдан Токио (Япония) (шунда инглиз теле һәм секретарьлар курсларын тәмамлый) шәһәрләрендә яши. 1935 елга кадәр татар эмигрантлары балалары укыган Ислам мәктәбендә укыта. 1935 елның 14 февралендә Гаяз *Исхакый* башлангычында Кытайның Мукден шәһәрендә уздырылган Төрки-татарларның I Ерак Көнчыгыш корылтаенда (Мукден конгрессында) катнаша. Гаяз Исхакый Европага киткәннән соң (1936), Мукденда чыгып килгән «*Милли байрак*» газетасындагы (1935–1945) баш мәкаләләрнең күбесе аның тарафыннан языла.

Газетаның 1937 елгы август санында Р.Мөхәммәдишнең «Габделкаюм Насыйри (вафатына 35 ел булу уңае белән)» мәкаләсе дөнья күрә. Автор галим турында аңарчы билгеле булмаган ниндидер яңа мәгълүмат бирү максатын куймавын, бәлки чит илдә тәрбияләнеп үскән яшь буын вәкилләренә аны таныту бурычын алга сөрүен ассызыклый, аны «ана телебезне сарыф, нәхү калыпларына салуда хезмәт итүче мәгарифче, телче, халкыбызны караңгылыктан яктылыкка чыгару ният белән уку-укыту ысулларын Көнбатыш Ауропа юлына салуда гомере буенча эшләүче язучы» дип атый, «Насыйри исә озын еллар дәвам иткән «календарь»ләре аркылы халык әдәбияты, иске ырымнар белән таныштырып, халкыбызның мәгънәви барлыгын күрсәтү юлында эшләде. Каюм Насыйриның бөек хезмәтләрендә иң мөһим урын тоткан телебезне гарәп, фарсы тәэсирләреннән әрчү, халык сөйләшкән телдә язуны уртага кую булды... Каюм Насыйри тарафыннан гамәли рәвештә ачылган сукмактан бара башлаган Идел буеның милли-мәдәни, мәгънәви тормышы елдан-ел киңәйде. Әдәби тел байый, матурлана барды. Насыйринең «календарь»ләреннән Идел буе вакытлы матбугатының «Вакыт»ы, «Шура»сы мәйданга килсә, аның тәрҗемәләрдән тәртип иткән беренче һәндәсә, хисап китапларыннан җәдид мәктәпләребезнең тәртипле дәреслекләре үҗүдка аштылы», — дип яза.

1943 елда «Милли байрак» газетасының баш мөхәррире Ибраһим Дәүләткилдегә кияүгә чыга, аның фамилиясенә күчә. 1945 елда башта япон хәрби миссиясе, аннары совет контрразведкасы органнары тарафыннан кулга алына; 1946 елда Байкал арты хәрби округы хәрби трибуналы аны 10 елга ирегеннән мәхрүм итә; ун ел дәвамында Новосибирск өлкәсендә ГУЛАГ системасындагы хезмәт лагерында, аннан соң алты елга якын сөргендә була. 1961 елдан Казакъстандагы Петропавловск (Кызылъяр) шәһә-

рендә яши, 1967 елга кадәр мәктәптә инглиз теле укыта. 1989 елда Казанда вафат була.

Чыг.: Габделкаюм Насыйри (вафатына 35 ел булу уңае белән) // Милли байрак. 1937. 13 август; Рокыя Дәүләткилде: бер татар хатынының ачы язмышы. Казан, 2005.

Әд.: Усманова Л. Газета «Милли байрак» — «Энциклопедия» татарской эмиграции // Татарские материалы в Урало-Алтайском архиве Хаттори Сиро. Казань, 2016.

И.Х.Хәлиуллин.

МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ Фатих Гариф улы (25.12.1883, Казан губернасының Казан өязе (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы) Олы Җәке авылы – 30.01.1950, Казан), Татарстанның сәламәтлек саклау эшлеклесе, гигиена белгече, медицина фәннәре докторы (1935), профессор (1933).

Казан университетының медицина факультетын тәмамлаганнан соң (1917), Гражданнар сугышы фронтларында өлкән табиб, бригада табибы буларак хезмәт итә. 1920 елдан Казанда: 1922–1927 елларда ТАССР Сәламәтлек саклау халык комиссариатында бүлек мөдире, ТАССР Сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары, ТАССР Сәламәтлек саклау халык комиссары. 1927–1932 елларда Казан ГИДУВының җәмәгать-көнкүреш гигиенасы кафедрасында, бер үк вакытта, 1930–1935 елларда Татарстан җәмәгать-көнкүреш гигиенасы институты директоры. 1932–1950 елларда Казан медицина институтының җәмәгать-көнкүреш гигиенасы кафедрасы мөдире.

Хезмәтләре сәламәтлек саклауны оештыруга, демографиягә, медицина статистикасына, татар балаларының физик яктан үсешен бәяләүгә карый.



Ф.Г.Мөхәммәдъяров

Каюм Насыйриның медицина һәм гигиена буенча белемнәрне таратуга керткән өлеше хакындагы 1948 елда дөнья күргән «Каюм Насыйров — татарлар арасында медицина-санитария буенча белемнәрне популярлаштыручы» мәкаләсендә әдипнең үз заманы медицина әдәбияты һәм ике фармацевтның 1885 елда Мәскәүдә нәшер ителгән китабы нигезендә язылган биш бүлектән торган «Үләнлек вә чәчәклек», 1885 елгы календаренда урнаштырылган 250 дару чаралары исемлеге һәм «Әхвале бәдән инсан вә хифыз сыйххәт» («Кеше организмының халәте һәм гигиена»), 1894 елгы календарьга кушымта буларак чыгарылган «Мәнафигы әгъза вә кануны сыйххәт» [«Кеше органнарының функцияләре һәм гигиена кагыйдәләре»], 1890 елгы календарьда урын алган «Бала тәрбия кылгучы хатынларга нәсыйхәт» һәм «Әхвале шәрәб әт-дөхан» [«Тәмәке тартучының хәле»], 1891 елгы календарьда басылган «Тәрбия», шигъри рәвештә язылган һәм 1896 елда брошюра сыйфатында дөнья күргән «Исереклек заманы», 1904 елда шулай ук брошюра рәвешендә нәшер ителгән «Әхлак рисаләсе» әсәрләре тикшерелә, аларга югары бәя бирелә; галим хезмәтләренең дәвалау-кисәтү медицинасының барлык мәсьәләләрен дә диярлек (дәвалау медицинасы, авыруларны булдырмау, балаларның сәламәтлеген саклау, социаль авырулар белән көрәш һ.б.) колачлавы, шуннан күренгәнчә, К.Насыйриның халыкның сәламәтлеген саклау мәсьәләләре белән тирән кызыксынуы һәм заманча рус, гарәп, фарсы

медицина әдәбияты белән яхшы таныш булуы, аның шул рәвешчә иске хорафатларга, им-том күренешләренә ачыктан-ачык каршы чыгуы, медицина-гигиена белемнәрен таратуы нәтиҗәсендә татар халкы өчен медицина фәне казанышлары белән танышу мөмкинлеге ачуы һәм шәхси сәламәтлеккә, авыруларга карата җаваплы мөнәсәбәт булдыру өчен җирлек тудыруы ассызыклана.

Хезм.: К вопросу об изучении воспроизводства поколений // Казанский медицинский журнал. 1930. № 6; К вопросу об изучении переживаемости взрослого татарского населения. Казань, 1930; Каюм Насыров как популяризатор медико-санитарных знаний среди татар // Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвященных 120-летию со дня рождения). Казань, 1948; Опыт изучения плодовитости женщины татарки и переживаемости её ребёнка. Казань, 1930; Самодеятельность трудящихся в деле охраны здоровья. Казань, 1935.

Әд.: Видные учёные отечественной медицины и здравоохранения — питомцы Казанского медицинского института. Казань, 1989; Профессор Фатых Гарифович Мухамедьяров. Казань, 1973.

И.Х.Хәлиуллин.

МӨХӘММӘТГӘРӘ́ЕВА Гөлфия Вагыйз кызы (14.02.1954, Татарстанның Мөслим районы Нарат Асты авылы), педагог, төбәкне өйрәнүче, публицист. РФнең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре (2001). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2003).

Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, 1971–1973 елларда Мөслим районы Татар Бүләре урта мәктәбендә укытучы, 1973–2009 елларда Түбән Табын урта мәктәбендә татар теле



Г.В.Мөхәммәтгәрәева

һәм әдәбияты укытучысы, уку-укыту бүлеге буенча директор урынбасары булып эшли. Бер үк вакытта, 2014 елдан, «Тәртип» радиосында «Тел дигән дәрья бар», «Сабыйга», «Кыйссадан хисса», «Тормыш тәрәзәләре», «Саф вә раушан көзге» һәм «Тукай укулары» тапшыруларының авторы һәм алып баручысы. «Авыл утлары» (Мөслим районы), «Татарстан яшьләре», Мәгърифәт», «Киңәш һәм тәрбия» газеталары, «Мәгариф», «Фән һәм мәктәп» журналлары белән хезмәттәшлек итә.

Хезмәтләре татар мәгърифәтенә, халык педагогикасына, авыллар тарихына, «Тәртип» радиосы тапшыруларын өйрәнүгә карый.

Мөслим районының Мактаулы гражданы, Россия Президенты гранты иясе. Бөтендөнья татар конгрессының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

Хезм.: Мәгърифәткә багышланган гомер. Казан, 2011; Тел күрке — сүз. Мөслим, 2012; Дөнья сүзе — бер бүләк. Казан, 2021; Урман иле — Нарат Астым. Казан, 2024 (автордаш).

Әд.: Даутова Г.М. Яшәү шигаре: Барысы да халкым өчен // Мәгариф, 2020. № 6.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МӨХӘММӘТЖА́НОВ Ильяс Мулланур улы (02.09.1977, Киров өлкәсенең Вятка Аланы районы Урта Шөн авылы), педагог, методист, шагыйрь, филология фәннәре кандидаты (2009). Язучылар берлеге әгъзасы (2016). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2013).



И.М.Мөхәммәтҗанов

Казан педагогика университетының табигать белеме һәм география факультетын тәмамлый (1999). 1998–2002 елларда — Татар-Америка төбәк институтында, 2000–2003 елларда ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында аспирантурада укый. 1997–2006 елларда — Казандагы 21 нче урта гомум белем бирү мәктәбендә, 2006–2008 елларда — 30 нчы лицейда география укытучысы, бер үк вакытта, 2006–2010 елларда, Татар гуманитар-педагогика университетының көнчыгыш телләре факультетында методист һәм гарәп теле укытучысы. 2011–2013 елларда — Россия ислам институтында ислам икътисады һәм идарәсе кафедрасы доценты, теология факультетында «Яңа икътисади география», «Дөнья икътисады һәм халыкара икътисади мөнәсәбәтләр» һәм «Глобаль икътисадта халыкара икътисади мөнәсәбәтләр» курслары алып бара. 2008 елдан 27 нче гимназиядә гарәп теле һәм география укытучысы, 2017 елдан 133 нче урта гомум белем бирү мәктәбендә уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли.

Хезмәтләре гарәп теле, география, икътисади һәм социаль география дәреслекләре, методик уку-укыту әсбаплары төзүгә карый. Ул шулай ук туган төбәге — Киров өлкәсе табигатенә һәм фольклорына багышланган «Мәхәббәт дулкыны» шигырьләр җыентыгы (Г.Н.Сәгъдуллина белән берлектә) нәшер итә. 2013 елда үз җырларыннан тупланган «Юллар» альбомы дөнья күрә.

К.Д.Ушинский, В.И.Вернадский, М.В.Ломоносов медальләре, «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, ТР Мәгариф министрлыгы һәм РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнә. «Ел укытучысы», «Иң яхшы сыйныф җитәкчесе», «Иң яхшы укытучы», «Алгарыш», «Укытучы — эзләнүче» һәм башка бәйгеләрдә призлы урыннар яулый.

Хезм.: Использование приёмов татарской литературы на уроках географии (учебно-методическое пособие для учителей географии). Казань, 2008 (автордаш); Арабский язык. 5 класс: учебное пособие для общеобразовательных учреждений. Казань, 2011 (автордаш); Арабский язык. 6 класс: учебное пособие для общеобразовательных учреждений. Казань, 2013 (автордаш); Экономика международного туризма (учебное пособие). Казань, 2014; Экономическая и социальная география мира (учебно-методическое пособие). Казань, 2014.

Ф.Г.Камальтдинова.

МӨХӘММӘ́ТОВ Хисам Мөхәммәт улы (20.12.1914, хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән авылы – 30.12.1991, Омск шәһәре), әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты (1954).

1930 елда Свердловск шәһәрендә рабфак тәмамлый. Оренбург педагогия институтында белем ала, өзелгән укуын Казан педагогия институтында тәмамлый, шунда ук аспирантурада укый.

1954–1962 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. 1962 елда Алабуга педагогия институтында хезмәт укыта, соңрак Омск педагогия институтының эстетика кафедрасы мөдире итеп чакырыла.

Хезмәтләре 19 йөзнең соңгы чирегендә татар әдәбиятында мәгърифәт-

челек идеяләренә, Каюм Насыйри, Заһир Бигиев әсәрләрендә күтәрелгән проблемаларга карый. Татар әдәбиятының башка халыклар әдәбиятлары белән багланышларына, 1941–1959 еллар татар поэзиясенә багышланган һәм әүвәл Татарстан матбугатында чыккан мәкаләләре һәм очерклары соңрак «Татар совет әдәбияты тарихы» күмәк җыентыгында дөнья күрә. Аның шулай ук «Кыйссаи Йосыф», «Борынгы легендалар, риваятьләр һәм бәетләр», «XIII–XIV йөзләр әдәбияты» хезмәтләре дә әһәмияткә ия. Каюм Насыйри турындагы мәкаләләр авторы. Ул әдипнең тууына 130 ел тулу уңае белән язылган мәкаләсендә: «19 йөз азагында татар тормышындагы иҗтимагый хәрәкәт мәгърифәтчеләрнең прогрессив идеяләр өчен көрәше белән характерлы. Мәгърифәтчелек характеры демократик хәрәкәт иде. Аның үсешенә һәм билгеле бер формага керүенә, гомумән, алдынгы рус культурасы, фикер үсеше тәэсир ясады. Татар мәгърифәтчелек хәрәкәте шул чордагы киң катлау татар халкының һәртөрле эксплуататорларга каршы нәфрәтен һәм аның прогрессив омтылышларын чагылдырды. Бу чордагы татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле К.Насыйри иде. К.Насыйри, рус мәгърифәтчеләре кебек үк, буржуаз эксплуатациягә, буржуазия вәкилләренә каршы чыга. Аның мирасы бу ягы белән дә кыйммәтле. Ул завод хуҗаларының халыкны алдауларын фаш итә, бай хатыннарының, бай малайларының культурасызлыгын, эгоистик психологияләрен ачып бирә. К.Насыйриның крестьян массасы белән тыгыз бәйләнештә булуы, үзенең әсәрләрендә билгеле күләмдә аларның тормышына туктала баруы, табигый, очраклы хәл түгел. Ул һәр елны кат-кат авылларга чыга, авыл халкы белән аралашып йөри. К.Насыйри яшәгән һәм иҗат иткән чорда, башка хезмәт ияләренеке шикелле крестьяннарның да тормышы гаять дәрәҗәдә авыр икәнен ачык күргән, аларның газаплы кичерешләрен аңлаган һәм уртаклашкан...», — дип яза. Үзенең гомерен укыту-тәрбия эшенә багышлаган К.Насыйриның мәгариф мәсьәләсендәге төп идеалы татарлар өчен гимназияләр һәм башка рус мәктәпләре кебек уку йортларына ирешүдән гыйбарәт булуын ассызыклый.

Хезм.: Каюм Насыйриның «Исереклек хәлләре» исемле поэмасы турында (Тууына 130 ел тулу уңае белән) // Совет мәктәбе. 1955. № 1; Каюм Насыйри // Совет Татарстаны. 1955. 15 февраль; К.Насыйриның мәгърифәтчелек карашлары (Тууына 130 ел тулу уңае белән) // Совет әдәбияты. 1955. № 2; Татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеяләре. Казан, 1961; Выдающийся татарский просветитель // Советская Татария. 1955. 15 февраля.

Әд.: Әхмәтҗанов М. Хисам ага хакында берничә сүз // Татар иле. 2004. № 51.

Ф.С.Гыйниятуллина.

МӨХӘРРӘ́МОВ Мидхәт Кәрим улы (27.04.1922, Башкортстанның хәзерге Мәләвез районы Җиргән авылы – 07.03.1993, Казан), тарихчы, тарих фәннәре докторы (1964), профессор (1967), ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1972, 1982). Бөек Ватан сугышында катнаша (капитан, танкист).

Казан юридик институтын тәмамлый (1948). 1938–1940 елларда Казан элемтә техникумында эшли. 1951 елдан — СССР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында: 1959–1963 елларда — тарих секторы мөдире, 1963–1982 елларда — директор.

Хезмәтләре Татарстанда Гражданнар сугышы, милли дәүләт төзелеше тарихына карый. «Татарстан АССР

тарихы» (1960, 2 нче том; 1980), «Татарстан партия оешмасы тарихы очерклары» (1962), «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр» («Борцы за счастье народное», 1967), «Татарстан АССР тарихы: иң борынгы заманнардан безнең көннәргә кадәр» (1968), «Борынгы шәһәрнең яшьлеге» (1978), «Татарстанда мәдәни революция (1917–1937 еллар)» (1986) һәм башка күмәк хезмәтләр авторларының берсе. Октябрь революциясе, Гражданнар сугышы, ТАССР төзелү тарихына караган документлар һәм материаллар җыентыгын әзерләүдә катнаша.

Каюм Насыйриның тормыш юлына һәм эшчәнлегенә багышланган мәкаләләрендә (күбесе Яхъя Абдуллин белән автордашлыкта языла), аерым алганда, 1976 елда дөнья күргән «Аталы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Каюм Насыйри һәм аның заманы» мәкаләсендә, галим яшәгән чор дини идеология тулаем хакимлек иткән вакыт булудан бигрәк татар халкы тормышына алдынгы карашлар үтеп кергән, татар һәм рус халыклары арасында аңлашу тирәнәя барган заман буларак сыйфатлана, әлеге ике халык мәдәниятләренең үзара якынаюында К.Насыйри гамәли эшчәнлегенең һәм фәнни хезмәтләренең тарихи колачлы әһәмияткә ия булуы күрсәтелә; мәгърифәтче эшчәнлегенең иреккә, тигез хокуклылыкка һәм халыклар арасындагы дуслык мөнәсәбәтләренә, милли изүгә каршы юнәлтелүенә игътибар бирелә; аның төрле фәннәргә (әдәбият, тарих, археология, этнография, халык медицинасы, этика һәм эстетика, география, ботаника, зоология, математика, физика, педагогика) караган 40 ка якын хезмәт язып бастыруы, тарих һәм этнография өлкәләрендә татар халкының этник үзбилгеләнүе һәм үзаңы, килеп



М.К.Мөхәррәмов

чыгышы һәм теленең үзенчәлеге, мөстәкыйльлеге мәсьәләләрен көн тәртибенә куюы, табигать күренешләрен материалистик асылда аңлатуы югары бәяләнә; галим традицияләренең аннан соңгы буын вәкилләре тарафыннан төрле юнәлешләрдә дәвам иттерелүе, кайберләренең аны үзләренең остазы дип атаулары (Мөхетдин *Корбангалиев* һ.б.), эшчәнлегенең игелекле йогынтысын танулары (Габдулла *Тукай*, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Фатих *Әмирхан,* Галимҗан *Ибраһимов* һ.б.) бәян ителә.

Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, ике Кызыл Йолдыз ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Күренекле татар галиме һәм демократы // Татарстан коммунисты. 1975. №5 (автордаш); Из истории иностранной военной интервенции и гражданской войны на территории Татарии (1918–1920 гг.). Казань, 1954; Октябрь и национально-государственное строительство в Татарии. М., 1969; Гордость татарской культуры: к 150-летию со дня рождения Каюма Насыри // Советская Татария. 1975. 13 фев. (автордаш); Выдающийся татарский мыслитель-демократ // Коммунист Татарии. 1975. №1 (автордаш); Каюм Насыри и его эпоха // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Әд.: Памяти М.К.Мухарямова. Казань, 1995.

И.Х.Хәлиуллин.

МУ́СИН ГАЙСА́ ЙОРТЫ́, Казан шәһәрендә урнашкан тарих-архитектура истәлеге (Париж Коммунасы урамы, 24 нче йорт). Эклектика юнәлешле

классицизм элементлары булган ике катлы кирпеч бинаны 1880 елда периметраль рәвештә архитектор П.И.Романов проекты буенча икенче гильдия сәүдәгәр Гайса хаҗи Мусин (1816–1887) төзетә.

Мусин Казан мещаннары гаиләсендә туа, 1856 елда мануфактура товарлары белән сәүдә итә башлый. Аның улы Мөхәммәтсадыйк 19–20 йөзләр чигендә эре татар эшмәкәре һәм җәмәгать эшлеклесе буларак таныла, 1912 елда мещан Мөхәммәтгали Мусин белән сәүдә йорты оештыра, алдынгы фикерләрне яклый, Галимҗан Баруди тарафдары һәм фикердәше була.

Әлеге йортта 1885–1893 елларда Каюм Насыйри яши. 1885 елда янгын чыгып, китапханәсенең бер өлеше зыян күрә, китаплары һәм кулъязмалары яна. 1892 елда ул туганы Бәдигъ мөәзин *Хөсәенов* йортына күченә.

Әд.: Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVIII гасыр ахыры — XX гасыр башы). Казан, 1995. № 100; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. Казань, 1993. № 1065.

И.Х.Хәлиуллин.

Н

НАСЫЙРИ́ Габделкаюм Габденнасыйр улы, шул ук — Каюм Насыйри.

НАСЫЙРИЛА́Р НӘСЕЛЕ́, Каюм Насыйриның якын һәм ерак кардәшләре, нәсел-нәсәбе.

Каюм Насыйри нәсел-нәсәбен барлап, *шәҗәрә* төзи. Шәҗәрәдә тугызынчы бабасына кадәр ачыклап, элгәреләре турында бай мәгълүматлар китерә. Аның истәлекләреннән һәм шәҗәрәләрдән күренгәнчә, ата ягыннан бабасы Хөсәен Мукаев (1760–?) әтисе Әлмөхәммәттән яхшы дини тәрбия һәм белем ала. Хөсәен Әлмөхәммәт улы күп еллар Югары Шырдан (хәзерге Кече Шырдан) авылында имам булып тора. Ул нәхү (синтаксис) буенча зур белем иясе була. К.Насыйриның мәгълүматларына караганда, Х.Мукаев грамматика буенча — «Шәрхе мелла», дин нигезләре буенча — «Мисбах», синтаксис буенча — «Сарыф һәваи» исемле китаплар яза. Аның Коръәнне күчереп язу остасы даны тирә-якка тарала. К.Насыйри үз истәлекләрендә бабасы турында: «Үз гомерендә берничә йөз Коръәнне күчереп язгандыр», — дип хәбәр итә. Бабасының өч улы була: Габденнасыйр (әнисе — Хөсәен мулланың беренче хатыны Фазыйлә Әхмәтова), Мөхәммәтгалим һәм Хөснетдин (әниләре — Хөсәен мулланың икенче хатыны Ширти Уразаева).

Х.Мукаевның олы улы Габденнасыйр *Хөсәенов* (1786–1872) — К.Насыйриның атасы — күп фәннәрдән белемле кеше була. Югары Шырдан мәхәлләсенә имам итеп куелыр алдыннан, 1812 елда Сәлим кызы Фатыйма (1798–1867, Югары Шырдан) белән никахлаша. Габденнасыйр белән Фатыйма Хөсәеновлар биш угыл һәм бер кыз тәрбияләп үстерәләр: Габделхәй, Бибиҗәмилә, Габделкаюм (Каюм Насыйри), Габделгани, Габделвәли, Габделкави.

Габденнасыйр Хөсәенов балаларын үзе укыта, аларны кечкенәдән иҗтиһад тәгълиматы белән таныштыра. Эшмәкәрлеккә сәләтле улларын — сәүдәгәрлеккә, белемгә һәвәсләрен укуларын дәвам итүгә юнәлтә. Габделкаюм белән Габделкавидан кала өч улын сәүдәгәрлеккә әзерли. Г.Хөсәенов вафаты алдыннан: «Угъланнар, миннән соң, олыгыз олы, кечегез кече булсын» дигән васыять сүзләре әйтеп калдыра, балаларының бер-берсенә терәк булып, мул тормышта яшәүләрен тели. Бер-берсенә язган хатларыннан күренгәнчә, Габденнасыйр белән Фатыйманың балалары үзара тату һәм аралашып, бер-берсенә һәм эти-әниләренә матди ярдәм күрсәтеп яшәгәннәр.

Габделхәй Габденнасыйр улы (1820, Югары Шырдан — 17.11.1890, Казан) — К.Насыйриның абыйсы, эшмәкәр. Габденнасыйр, улының сәүдәгәрлек сәләтен күреп, җыйган акчасын һәм малын бирепә, аны гаилә капиталы башына билгели. Ул Мәскәүдә баштарак сабын, аннары шәм җитештерү

фабрикасы (1861) ача. 1858 елда Себер бае Гибай кызына өйләнә. Габделхәйнең Мәскәүдә үз йорты булган дип фаразлый алабыз, чөнки Каюмның абыйсына язган бер хатында адресы: «Мәскәүгә, Данилов монастыре янында үз йортында яшәүче сабын ясау остасы Казан татары Габделхәй Насыйровка», дип күрсәтелгән. Габденнасыйрның Мәскәүдәге уллары һәм туганнары сату-алу эшләре алып барса, Казандагылары аларга кирәкле әйберләрне, башлыча агач әрҗәләр җибәреп торалар. Габделхәй Киев, Курск («Коренной») ярминкәләренә һәм Түбән Новгородтагы Мәкәрҗә ярминкәсенә еш йөри. Хөсәенов фамилиясен Казанскийга алыштыра. 1874 елда туган авылында мәчет салдыра. Әтиләре вафатыннан соң улларының сәүдә-эшмәкәрлек өлкәсендәге эшләре сүлпәнәю сәбәпле, Габденнасыйрның бертуганы Мөхәммәтгалим Мәскәүдәге фабриканы саттыргач, Габделхәй Югары Шырданга кайтырга мәҗбүр була, әмма, авылда тору уңайсыз дип, Казанга китә. Анда йорт сатып алып, кибет ачмакчы була, ләкин эшләре алга бармый. Туганнарыннан читләшә, финанс хәлен яшерә. Габделхәйнең Яңа татар бистәсе зиратында кабер ташында: «Күлли Нәфсин заикател-мәүт (һәрбер җан үлемне татыр). Тарихе румия илән 1890 нчы сәнә нуябер 16 нчы көнендә Юкары Шырдан иленең Габделхәй мелла Габденнасыйр угылы 72 яшендә даре фәнадин. Даре бәкаййә рихләт әйләде. Аллаһы тәгалә Гарикъ рәхмәт кыйлсын. Амин. Аллаһы тәгалә галәйһум рәхмәтән васигатә (Аллаһы тәгаләнең аларга рәхмәте киң булсын)» дигән сүзләр уелган.

Габделхәй Казанскийның эшмәкәрлек шөгылен улы Габделмән (? — 19.09.1912, Казан) дәвам итә. Сәүдә, китаплар җыю белән шөгыльләнә. 1904 елда «Звонок һәм никель һөнәре» дигән китабы басыла. Аның Казанда берничә йорты була: Санников утары (беренче гильдия сәүдәгәр Ибраһим Баязитовтан сатып ала; хәзерге Тукай урамы, 12 нче йорт); хәзерге Тукай урамындагы 7 нче йорт (19 йөзнең 2 нче яртысында төзелгән); К.Насыйри берара Габделмән Казанскийның өченче йортында (хәзер Галиәсгар Камал урамында) яши. К.Насыйриның «Исагуҗи» кулъязма китабында аны Габделмәнгә бүләк итүе турында язма бар. Шулай ук китапта Габделмәннең шәхси мөһере куелган. Авыл тарихын өйрәнүче К.В.*Минкин* укыган метрика кәгазьләре һәм туганнарының мәгълүматлары буенча 1890 елның 19 декабрендә Югары Шырданда Габделмән Габделкави кызы Бибихәбирә белән никахлаша.

Бибиҗәмилә Габденнасыйр кызы (1822, Югары Шырдан – ?) — К.Насыйриның бердәнбер кыз туганы. Әтисе аны үзе укыта, Кармыш авылы муллысы Нигъмәтулла улы Мөхәммәтвәлигә кияүгә бирә. Аларның уртак өч балалары туа: Бибиҗәдирә, Бибиҗәзилә (20.06.1845 – 1885), Бибикәри-



Габделмән Казанский.

мә. Бибиҗәзилә Олы Шырдан авылы (хәзер Яшел Үзән районында) муллысы Галиуллага (1829–?) кияүгә чыга. Бу нәсел дәвамчылары әле дә Олы Шырдан авылында яши.

Габделгани Габденнасыйр улы (1829, Югары Шырдан – ?) — К.Насыйриның өлкән энесе. Ул, абыйсы Габделхәйнең Мәскәүдәге сабын җитештерү предприятиесендә күпмедер эшләгәч, Себергә китә. К.Насыйрига язган хатларыннан күренгәнчә, 1867 елларда Нерчинск округы Нарәкә прискасында староста вазифасын башкара. Рус кызына өйләнә. Себер климаты Габделганинең сәламәтлеген нык какшата, һәм ул чит җирләрдә вафат була.

Габделвәли Габденнасыйр улы (1831, Югары Шырдан – ?) — К.Насыйриның уртанчы энесе. Ул Мәскәүдә яши, абыйсы Габделхәйгә сату-алу эшләрендә булыша, аның белән ярминкәләргә йөри. 1854 елларга кадәр Мәскәүдә яшәгәнлеге мәгълүм. Өйләнә, угыл үстерә.



Хәбирә Насыйрия (басып тора) туганнары арасында. 1902 елга кадәр.

Габделкави Габденнасыйр улы (09.05.1833, Югары Шырдан – 24.02.1901, шунда ук) — К.Насыйриның кече энесе. Ул, төпчек ир бала буларак, күпчелек татар гаиләләрендәге кебек ата-ана нигезендә кала. Атасы Габденнасыйр теләгәнчә, туган авылында имам булып тора. 1864 елның 12 мартында авыл мәчетенә имам-хатип итеп куела. 1872 елдан мәктәптә шәкертләр укыта башлый. Балалары: Хәбирә (1882, Югары Шырдан – 1912, Казан), Габдрахман (20.09.1896, Югары Шырдан – 1944, шунда ук). Габделкави авыл зиратына җирләнә, кабер ташы сакланган.



Габдрахман Хөсәенов. 1918 еллар

Хәбирә *Насыйрия* (әнисе Маһикамал Әхмәтҗан кызы) агасы К.Насыйри эшчәнлеген дәвам итүче туганнарының берсе. Яшьли вафат була.

Габдрахман Хөсәенов Казан университетын тәмамлый. 1917 елгы Октябрь революциясеннән соң укытучылык эше белән шөгыльләнә: Зөя, Казан шәһәрләре, Югары Шырдан авылы мәктәпләрендә физика укыта. Аның 3 кызы була (Халә, Лия, Бәррә). Лия (1923–1930) бала вакытта вафат була. Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылындагы К.Насыйри исемендәге музей Кече Шырдан авылыннан күчерелгән Габдрахман йортында урнашкан. Ул бу йортны атасы Габделкави утары нигезендә 1925–1926 елларда салган була. Габдрахманның хатыны Р.Ф.Хөсәенова (04.07.1897 – 1970, Киев шәһәре) 1947 елда аны Олы Ачасыр авылы кешесенә сатып җибәрә (Шулай ук кара:


Архитектура-этнография комплексы).

Хәзерге вакытта Габденнасыйр Хөсәенов нәселен Габдрахман варислары дәвам итә. Хөсәенова Халә (1922 – ?) Мәскәү тимер юл транспорты институтын тәмамлый. 1956 елдан Украинаның Киев шәһәрендә, тимер юл транспорт оешмасында инженер вазифасын башкара. Бариева Бәрра (13.03.1925 – 19.06.2009) Казан медицина институтын тәмамлый, балалар табибы булып эшли. Кече Шырдан кешесе Габдрахманга (1923–2003) кияүгә чыга, Фәрит һәм Илдар исемле уллар үстерәләр. Бәрра һәм Халә ханымнар 1996 елда Кече Шырдан авылының башлангыч мәктәбендә булалар, авыл халкы белән аралашалар. Казанда *Каюм Насыйри музеен* ачуга зур өлеш кертәләр, аңа Габденнасыйр нәселе, К.Насыйри белән бәйле күп кенә тарихи экспонатлар, фотолар бүләк итәләр, истәлекләр калдыралар. К.Насыйри төзеп калдырган шәҗәрәнең (1880) аннан соңгы буыннарын барлыйлар.

Халә Хөсәенованың улы Илья Семёнович Хөсәенов, Киев инженер-төзелеш институтын тәмамлый. Бәрра Бариеваның уллары — Бариев Фәрит Габдрахман улы (05.10.1949 – 2010) Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый, шунда ук эшли; Бариев Илдар Габдрахман улы (1951 елда туган) Казан университетының геология факультетын тәмамлап, «Татнефть» берләшмәсендә эшли; геология фәннәре кандидаты. Илдарның оныгы Артур да үз нәселенең тарихы белән кызыксына, эзләнүләр алып бара.



Б.Г.Бариева. 1954 ел



И.Г.Бариев. 2023 ел



Н.М.Игъламова

Игъламова Наилә Мәхмүт кызының (30.05.1939) әнисе Әминә ягыннан нәсел җепләре Хөсәенов-Насыйровларга барып тоташа. К.Насыйри төзегән шәҗәрәдә Наиләнең әбисе (әнисенең әнисе) Факиһә һәм аның бертуганы Әхмәт Хөсәеновларның да исемнәре бар. Факиһәнең бабасы Мөхәммәтгалим белән К.Насыйриның атасы Габденнасыйр бертуганнар. Бу ике гаилә бер-берсе белән аралашып, ярдәмләшеп яшәгән. Казанга килгәндә



Мөхәммәтгалим хәзрәт хатыны һәм оныклары белән (хатыны кулында Факиһә — Н.М.Игъламованың әбисе).

Габденнасыйр уллары белән Мөхәммәтгалим өендә очраша торган булган. К.Насыйри гомеренең соңгы елларында аның улы, 5 нче мәхәллә мәчете имамы Мөхәммәтбәдигь мөәзин *Хөсәенов* йортында яши. Н.Игъламовага әбисе Факиһә К.Насыйри белән еш кына сөйләшеп утырулары, аның бик белемле кеше булуы турында сөйли торган була. Ул үзе дә мәгърифәтче турындагы истәлекләрне, хатирәләрне кадерләп саклый. Н.Игъламова Казан төзелеш институтын тәмамлаганнан соң (1964), «Татгражданпроект»та инженер-җылылык технигы булып эшли. Татарстан һәм Казан биналарын, аерым алганда, Республика клиник хастаханәсе, Кремль урамында прокуратура биналарын проектлауда катнаша, Казан сөт комбинаты, җылылык трассалары һәм күп кенә торак йортларның һәм мәдәният-көнкүреш хезмәте күрсәтү биналарының җылыту һәм вентиляция системалары проектлары аның җитәкчелегендә эшләнә.

Нияз Рәүф улы Игъламов та (1976 елда туган) — шушы нәселнең бер буыны. Татарстан мәдәнияте өлкәсендә танылган шәхес, театр тәнкыйтьчесе.

ТРның халык рәссамы Р.Г.*Шәмсетдиновның* әнисе ягыннан Сәгыйтовлар нәселе К.Насыйрига барып тоташа. Рәссамның ерак бабасы Сәгыйд бине Әхмәд *әш-Шырдани* белән К.Насыйриның әнисе Фатыйма бертуганнар була.

ТР Эчке эшләр министрлыгында озак еллар хезмәт күйган К.В.Минкинның әтисенең ике әбисе — Нәфисә һәм Мәймүнә — бертуганнар, аларның әтиләре Хөснетдин К.Насыйриның әтисе Габденнасыйр белән бертуган. Камил Вәкил улы 20 ел дәвамында үз нәселен өйрәнә: Мәскәү, Уфа шәһәрләре һәм Татарстан архивларында булып, 14 буынын ачыклый; Кече Шырдан тарихына, шул авыл кешеләренә нисбәтле күп кенә тарихи мәгълүматлар туплый. Әтисе Минкин Вәкил Кәлимулла улы (1923–1992) Казан «Вакууммаш» җитештерү берләшмәсе директоры (1972–1980) булып эшли.

Эколог, биология фәннәре докторы, профессор, Казан университеты-



Насыйрилар нәселе Кече Шырдан авылында. 2015 ел.

ның Идарә, икътисад һәм финанслар институтының табигать төзелеше һәм судан файдалану кафедрасы мөдире Н.М.Минһаҗеваның да (1956 елда туган) әнисенең ике әбисе – Нәфисә белән Мәймүнә — К.Насыйриның туганнан туган сеңелләре. Минһаҗевлар гаиләсендә Нәфисә ханымның исеме әнисенең әбисе хөрмәтенә бирелгән дигән фараз яшәп килә.



Н.М.Минһаҗева

Илебез тарихында күренекле урын тоткан Кавиевлар нәселе дә Габденнасыйрның атасы Х.Мукаевка барып тоташа. Чуаш Республикасының Козловка районы Әлмән авылы мулласы Габделнасыйров (Нигъмәтуллин) Габделкавиның хатыны Нәфисә Хөснетдинова — К.Насыйриның туганнан туганы, аларның әтиләре Хөснетдин белән Габденнасыйр — бертуганнар. Мулла Кавинең эшен улы Сәлим Кавиев (1880–1942) дәвам итә, 1907–1917 елларда Урал якларында укытучы, мәктәп директоры булып эшли. Аның улы Х.С.*Кавиев*, беренчеләрдән булып, К.Насыйри бюстын ясый (сакланмаган). Хәмит Кавиевның улы Илгиз (1941 елда туган) уллары һәм оныклары белән Казанда яши

А.Н.*Юбәйдуллина* — әнисе ягыннан К.Насыйриның ерак туганы, Кече Шырданда мәгърифәтченең мирасын саклауда зур хезмәт куя.

Илебезгә лаеклы шәхесләр биргән, 18 йөздән мәгълүм Хөсәенов-Насыйровлар вәкилләре бүген дә аралашып яшиләр. И.К.Әхмәтов, Е.И.Бариева, И.Г.Бариев, Т.Ф.Бариев, Р.Ф.Галимова, Э.Ф.Кашапова, Д.Кашапов, Н.М.Игъламова, З.М.Кавиева, Ф.Ф.Кавиева, К.В.Минкин, Н.М.Минһаҗева, Р.Г.Шәмсетдинов, М.Г.Саттаров, А.Н.Гобәйдуллина һ.б. К.Насыйриның туган көнендә аның каберен зиярәт кылалар, ерак бабаларының туган җире Кече Шырдан авылында булып, әти-әни, әби-бабаларыннан ишеткән истәлекләре, яңалыклары белән уртаклашалар. Кече Шырдан халкы да бөек улын һәм нәселен онытмый. Авыл халкы ел саен К.Насыйри, аның ата-анасы, бакыйлыкка күчкән туганнары, авылдашлары рухына Коръән укыта, туган көне уңаеннан республикакүләм конференцияләр үткәрә. Шулай ук кара: Г.*Насыйров*.

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 2 томда. Казан. 1975. 2 т.

Әд.: Заһидуллин И. Нәсел шәҗәрәсе кайларга илтә // Казан утлары. 2024. №7, №8; Исламов Р., Хуҗиева Э. Кем ул Бәдигъ мөәзин? // Безнең мирас. 2024, № 12; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Загидуллин И.К. Семья татарского просветителя Каюма Насыри // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2024. № 4.

Ф.Г.Камальтдинова.

НАСЫЙРИЯ́ Хәбирә Габделкави кызы (1882, кайбер мәгълүматлар буенча 03.12.1874 — 1912), укытучы, тел галиме, фольклорчы. Каюм Насыйриның шәкерте һәм бертуганы Габделкавиның кызы.

К.Насыйри туганнары арасыннан үзенең язучылык, мәгърифәтчелек, фәнни эшчәнлекләренең дәвамчысы булуын теләгән. Шул хакта 1880 елда басылган шәҗәрәсендә дә искә ала. Бу мәсьәләдә кече энесе Габделкавиның кызына зур өметләр баглаган, чөнки Хәбирәдә белемгә зур омтылыш һәм язу-иҗат итү сәләтен күргән. Хәбирә К.Насыйри хезмәтләре йогынтысында тәрбияләнә, аның хезмәтләрен укый, аңардан белем ала. Мәгърифәтче галим исән вакытта ук Хәбирә гыйльми

һәм иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Аны халык авыз иҗаты әсәрләре, тел белеме мәсьәләләре кызыксындыра. Ул татар телендә кулланылган сүз-төшенчәләрне җыя һәм системага сала. 1902 елда бертуган Кәримовларның сәүдә йорты басмаханәсендә (кара: *Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф кою ширкәте*) аның «Мөлтәкат әл-лөгат нам фарси, гарәби вә төрки» исемле сүзлек китабы нәшер ителә. Әйтергә кирәк, ул — К.Насыйри йогынтысы һәм җитәкчелегендә барлыкка килгән хезмәт. 1904 елда Х.Насыйриянең «Мөзәкихә, яхуд әкъвале гарибә» («Мәзәк, яки Гаҗәеп гыйбрәтле сүзләр») исемле яңа китабы басыла. Күренекле тел галиме В.Х.*Хаков* аның әлеге хезмәтләренә югары бәя бирә. Авторның беренче «Мөлтәкат әл-лөгат нам фарси, гарәби вә төрки» хезмәтендә татар китапларына кергән гарәп, фарсы сүзләренә аңлатмалар бирелә, һәм ул, гомумән, тел мәсьәләләренә багышлана. Хезмәтнең кереш сүзендә автор төрки телдәге китапларның мәгънәләре аңлашылмаслык дәрәҗәдә гарәп, фарсы сүзләре белән чуарланган булуын әйтә. Гади укучы аңлашылмый торган гарәп, фарсы сүзләре алдында югалып калмасын өчен, Х.Насыйрия шушы хезмәтен тәкъдим итә. Сүзлектә иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә очраучы сүзләр дә урын алган. Уң яктан беренче графада — алфавит буенча гарәп, икенчесендә — фарсы, өченчесендә татар сүзләренең халыкка аңлаешлы әдәби телдә төгәл эквивалентлары бирелә. Бу факт үзе генә дә Х.Насыйриянең күп телләр белүен һәм заманы өчен мөһим эш башкаруын раслый. Әлеге хезмәт өстендә эшләгәндә ул К.Насыйри хезмәтләрен өйрәнеп кенә калмаган, аңардан киңәшләр дә алган. Бөек мәгърифәтче иҗатының беренче көннәреннән үк татар әдәби теленең халыкчанлык юнәлешен яклап чыга. Яшь галимә телдәге үзгәрешләргә, яңа сүзләргә аеруча игътибар итә һәм аларны сүзлегенә теркәп куя. Китапта матур әдәбиятны тулыландыру, сөйләм телен бизәү өчен кулланылган фразеологик әйтелмәләр дә (аяк ялы, күңел йөге, корсак колы һ.б.) бирелә. Х.Насыйриянең «Мөзәкихә, яхуд әкъвале гарибә» китабында халыкчан телдә язылган 100 гә якын мәзәк урын алган. Ул К.Насыйри хезмәтләре үрнәгендә төзелгән. Мәзәкләр кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтен, шул чор вакыйга-хәлләрен чагылдыра. Х.Насыйриянең язмалары «Казан мөхбире» (1905–1911) газетасының «Хатын-кызлар» сәхифәсендә даими басылып килә. Агасы К.Насыйри башлаган юнәлешне ул лаеклы рәвештә дәвам итә. 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр, татар хатын-кызларының алдынгы бер вәкиле буларак, Х.Насыйрия дә татар мәдәнияте тарихында лаеклы урын били.



Х.Г.Насыйрия

Әд.: Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. Казан, 1998; Хаков В.Х. Хәбирә Насыйрия // Социалистик Татарстан. 1987. 7 март.

Ф.Г.Камальтдинова.

НАСЫ́ЙРОВ Габделбарый (1881, Казан губернасының Чабаксар өязе (хәзерге Чуаш Республикасы Козловка районы) Янгильдино (Кармыш) авылы – ?), басмаханә хезмәткәре; Каюм Насыйриның әнисе ягыннан туганы һәм аның турында истәлек сөйләүче.

Әтисеннән яшьли ятим кала. Аның әтисе укымышлы, матур язулы һәм тиз яза торган кеше була. Шунлыктан ул гомере буе диярлек китап күчереп язу белән шөгыльләнә. Аның улы Габделбарый Казандагы «Промполиграф» оешмасында китап төпләүче булып эшли.

1945 елда язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт *Гали* тарафыннан Г.Насыйровтан К.Насыйри турында истәлек язып алына һәм 1948 елгы җыентыкта бастырыла. Автор үзенең хатирәсендә К.Насыйри белән горурлануы турында яза. Мәгърифәтче галим белән якыннан аралашу аңарда тирән тәэсир уята. Шундый очрашуларның берсен хәтерендә яңартып: «Хөснижамал абыстай [Габделбарыйның әтисенең сеңелесе] Каюм абыйдан да, Кави абыйдан да качмады. Баргач та алар белән озаклап сөйләшеп утырды һәм алар бер табынга утырып чәй эчте. Ул алар белән күбрәк гыйльми мәсьәләләр турында сөйләште, нинди дер китапларда үзе аңламаган мәсьәләләрне Каюм абыйдан сорашты. Каюм абый да аны үз итеп, аның белән озаклап сөйләшеп утырды. Ләкин мин аларның нәрсә турында сөйләшкәннәрен ачык хәтерләмим. Шушы беренче очрашудан соң да без Хөснижамал абыстай белән җәй көннәрендә берничә мәртәбә Шырданга бардык. Без барганда Каюм абый анда була иде. Бәлки, Хөснижамал абыстай аның кайткан вакытына туры китереп Шырданга барган булгандыр. Барган саен алар Хөснижамал абыстай белән бик якыннан озаклап сөйләшеп утыралар иде...», — дип искә ала.

Хезм.: Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Туулына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Ф.С.Гыйниятуллина.


НИЗА́МОВ Айдар Малик улы (22.08.1939, Татарстанның Әтнә районы Ключи-Сап авылы – 25.05.2024, Казан, туган авылында җирләнә), педагог, педагогия фәннәре кандидаты (1985), СССРның мәгариф отличнигы (1974), ТАССРның атказанган мәктәп укытучысы (1984). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2008).

Казан университетының биология-туфрак факультетын тәмамлый (1968). 1975–1983 елларда Әтнә районы мәктәпләрендә директор урынбасары, директор, ТР Мәгариф министрлыгының урта махсус уку йортлары бүлеге җитәкчесе вазифаларын башкара. 1983–1986 елларда — СССР Педагогика фәннәре академиясенең Һөнәри техник-педагогика фәнни-тикшеренү институтында гыйльми хезмәткәр; 1986–1992 елларда — Казан педагогия институтының мәктәп җитәкчеләре белемен камилләштерү факультеты өлкән укытучысы, доценты, кафедра мөдире, деканы; 1992–2000 елларда — 149 нчы татар-төрек лицее директоры, 2000–2005 елларда — Татар гуманитар институтының педагогия һәм психология, Татар гуманитар-педагогика университетының педагогика тарихы һәм этнопедагогика кафедралары доценты.

Хезмәтләре һөнәри белем, милли тәрбия, мәктәпләр белән идарә итү мәсьәләләреңә карый.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Һөнәр сайлаганда. Мәктәпләрдә профессиональ ориентация эшен оештыручылар өчен кулланма. Казан, 1981; Әдәплелек кагыйдәләре. Укучылар, педагоглар һәм әти-әниләр өчен кулланма. Казан, 1999; Бүгенге мәктәп: җитәкчелек нигезләре. Югары уку йортлары өчен уку



А.М.Низамов



Р.А.Низамов

ярдәмлеге. Казан, 2002; Милли мәктәп: тәрбия нигезләре. Казан, 2005.

Әд.: Гадел Ә. Өмет чаткысы гынамы // Шәһри Казан. 2005. 6 сентябрь; Тиңе булмаган кыйммәтле мирас // Мәгариф. 1999. № 8.

Ф.С.Гыйниятуллина.

НИЗА́МОВ Равил Авзал улы (17.09.1930, Татарстанның Зәй районы Бигеш авылы – 16.08.2007, Казан), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе, педагогия фәннәре кандидаты (1962), ТРның атказанган мәктәп укытучысы (1992). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2008).

Алабуга китапханә техникумын (1948), Казан педагогия институтын (1954) тәмамлый. 1948–1950 елларда — Кызыл Йолдыз районы китапханәсе мөдире. 1954–1957 елларда — Әгерҗе районының Иж-Бубый авылы урта мәктәбе укытучысы, 1957–1958 елларда Сарсак-Умга урта мәктәбендә директор булып эшли. 1958 елдан — Казан университетында: 1962–1963 елларда — тарих-филология факультеты деканы урынбасары, 1969–1979 елларда — педагогия кафедрасы мөдире. 1980–1990 елларда — ТАССР мәгариф министры. 1990–2001 елларда — ТР Мәгариф министрлыгының Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү институтында педагогия кафедрасы мөдире вазифаларын башкара.

1960–1990 елларда — РСФСР Педагогика җәмгыятенең Татарстан бүлеге рәисе, бер үк вакытта, 1980–1985 елларда, — ТАССР Югары Советы депутаты, 1990–1993 елларда — ТР Югары Советы депутаты.

Хезмәтләре педагогика гыйлеменә, татар халык педагогикасына, әдәп-әхлак мәсьәләләренә, хезмәт дәресләрендә мәктәп укучыларының активлыгын үстерүгә, студентларның уку эшчәнлекләрен оештыруның дидактик нигезләренә карый.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәт өчен», Н.К.Крупская исемендәге, «В.И.Ленинның 100 еллыгы» медальләре, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

Хезм.: Педагогик уйланулар. Казан, 1994; Көч һәм рух тамырлары: Әдәплелек дәресләре: 1–3 нче сыйныфлар өчен хрестоматия. Казан, 2000 (автордаш); Татар халык педагогикасы. Казан, 2002 (автордаш); Повышение активности школьников на уроках труда. Казань, 1971; Дидактические основы активизации учебной деятельности студентов. Казань, 1975.

Әд.: Биобиблиографический словарь. Казань, 2004; Т.3; Кто есть кто: авторы издательства «Магариф» Казань, 2002.

Ф.С.Гыйниятуллина.

НОГМА́Н (Ногманов) Мостафа Ногман улы (22.12.1912, Казан губернасының Царёвококшайск өязе (хәзер Арча районы) Кызыл Яр авылы – 04.09.1976, Казан), шагыйрь, тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1964). Бөек Ватан сугышында катнаша.

1937–1941 елларда Дүшәмбе педагогия институтын (1941), Көнчыгышны өйрәнү институтын (1951, Мәскәү) тәмамлый. 1931 елдан Татарстан һәм Таҗикстан мәктәпләрендә укыта. 1935–1937 елларда Дүшәмбе шәһәрендә Хәрби трибуналда сәркатип вазифасын башкара. 1945–1947 елларда «Пионерская правда» газетасының Татарстандагы үз хәбәрчесе булып эшли. 1953–1957 елларда — СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында. 1957–1959 елларда — Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә Шәрекъ кулъязмаларын өйрәнү бүлеге мөдире. 1960 елдан — Казан университетында фарсы һәм иске татар телләре укытучысы.

1941 елда «Давыллы еллар лирикасы» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. «Апрель җилләре» (1954), «Кокушкино таңнары» (1964) җыентыклары В.И.Ленинның Казан чоры тормышына багышлана. «Таң йолдызы» (1959), «Каеннар шаулый» (1967), «Иртәнге җырлар» (1973), «Акчарлаклар оча Иделдә» (1982) җыентыклары авторы. Шигырьләре нечкә лиризм, аһәңлелек белән аерылып тора. Композиторлар Р.Яхин («Оныта алмыйм», «Бөдрә таллар»), С.Садыйкова («Актаныш таңнары», «Арча кичләре»), шулай ук А.Ключарёв, М.Мозаффаров, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтовлар белән берлектә популяр җырлар һәм романслар иҗат итә. Н.Хикмәт, Рудаки, Г.Хәйям, А.Кадыйри әсәрләрен татар теленә тәрҗемә кыла. 17–18 йөзләрдәге кулъязма рус-татар сүзлекләрен өйрәнә.

К.Насыйриның Казан университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә* сакланган кулъязма дәфтәрләрдән гыйбарәт тел белеме, матур әдәбият, тарих, археология, географиягә, дәреслекләргә, календарьлар әзерләүгә, шәҗәрәләр төзүгә һәм башка темаларга караган алты дистә чамасы кулъязмасын (аларның берише төрле күләмдә кабатлана), ике дистәдән артык төрле хатларын үз эченә алган архивындагы 84 саклау берәмлеген барлап, тикшереп, 1958 елда Әбрар *Кәримуллин* мөхәррирлегендә Казан университеты нәшриятында К.Насыйри кулъязмаларына багышланган тасфирламасын дөньяга чыгара. Югары уку йортлары өчен фарсы, иске татар телләре буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы.



М.Н.Ногман

Медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри кулъязмалары: Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. 3 нче чыг. Казан, 1958; XVII–XVIII йөзләрдә русча-татарча сүзлекләр. Казан, 1969; Иске татар язуы үрнәкләре: югары уку йортларының филология бүлеге студентлары өчен уку китабы. Казан, 1971.

Әд.: Мадьяров Н. Күңелләрдә ул җыр булып яши // Шәһри Казан. 1997. 16 гыйнвар; Сөнгатев М. Яшьлек хыялларын җилкән итеп... // Казан утлары. 1982. № 12.

Г.М.Габделхакова, И.Х.Хәлиуллин.

НОГМА́НОВ Гыйльман (1885, Казан губернасының Зөя өязе Югары Шырдан авылы (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы) — ?), Каюм Насыйриның авылдашы һәм аның турында истәлек авторы. 1945 елда фольклорчы Хәмит *Ярми* аңардан К.Насыйри турында истәлек язып ала һәм 1948

елда җыентыкта бастыра.



Г.Ногманов

Г.Ногманов үзенең истәлегендә К.Насыйри белән аралашуы хакында: «...Каюм абзый үзе янында аш пешерүче, төрле йомышка йөрүче бер малай тота иде. Башта анда бик күп вакытлар бер Казан арты малае торган. Аннан соң менә безнең үзебезнең Шырдан авылының Талип абзый энесе Барый абзый торды. Ул анда озак тормады, Каюм абзыйның вак-төяк әйберләрен авылга алып кайтты. Озак та үтми, Каюм абзый безнең әтигә «малаен алып килсен» дип әйттергән. Әти ат җикте дә, шунда аш пешерерсең, укырсың да, — дип, мине Казанга алып барып, Каюм абзыйга малайлыкка бирде. Миңа ул вакытта 10–11 яшьләр булгандыр. Каюм абзый Кызыл мәчет урамында Әптелмән йортының кечкенә бер бүлмәсендә тора иде. Бүлмәнең бер генә тәрәзәсе бар иде. Бүлмә эчендә ике шкафта, өстәл өсләрендә төпләнгән китаплар бик күп иде. Мин һәркөнне иртә белән базарга барып ашау-эчү әйберләре алып кайта идем. Ул, ашау-эчү әйберләре бозылмасын дип, көннекөнгә генә алдыра иде. Ул бик аз сөйләшә. Үзенә кирәкне генә сорый, йомышка җибәрә. Чыгып киткәндә, «өйгә кеше кертмә» дип, бүлмәне бикләп чыгып китә иде. Мин анда озак тормадым, бары 7–8 көн генә торгач, элек үзендә торган Казан арты малае килгәч, мине кайтарып җибәрде», — дип искә ала. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Чыг.: Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Ф.С.Гыйниятуллина.

НУРИ́ЕВА Алмазия Хаҗи кызы (01.09.1928, Татарстанның Әгерҗе районы Салагыш авылы – 25.09.2005, Казан), укытучы, тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1961). РФнең Халык мәгарифе отличнигы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты.

Минзәлә педагогия училищесын (1946), Казан университетының тарих-филология факультетын (1953), шунда ук татар теле һәм әдәбияты кафедрасында аспирантура (1956) тәмамлый. 1946–1948 елларда Салагыш мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. 1956–1958 елларда — «Совет мәктәбе» журналының җаваплы сәркатибе. 1958–1961 елларда — ТАССР Халык мәгарифе министрлыгының дәреслекләр һәм программалар бүлеге башлыгы. 1961–1967 елларда — РСФСР Милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы фәнни хезмәткәре. 1967–1984 елларда — Казан университетының татар теле кафедрасы доценты.

Хезмәтләре татар әдәби теле тарихын өйрәнүгә, орфографияне камилләштерүгә, фәнни терминология нигезләрен эшкәртүгә, татар теленең лексик байлыгын, морфологик һәм синтаксик төзелешен тикшерүгә һәм методикага карый. Ул күп кенә дәреслекләр авторы, татар теленең орфографик сүзлеген төзүче.

«1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Ана теле буенча мөстәкыйль эшләр: 3–4 класслар өчен дидактик материаллар. Казан, 1964; Татар теленнән мөстәкыйль эшләр. 5 нче класс: Укытучыга кулланма. Казан, 1977; Татар теленең орфографик сүзлеге: Башлангыч мәктәп укучылары өчен. Казан, 1996; Татар теле: рус телендә белем бирүче дүртьел-

лык башлангыч мәктәпнең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен): Ике кисәктә. Казан, 2008.

Әд.: Туган телгә багышланган гомер // Мәгариф. 1998; Казанская лингвистическая школа. Казань, 2008. Кн.1; Кто есть кто: авторы издательства «Магариф». Казань, 2002.



А.Х.Нуриева

Ф.С.Гыйниятуллина.

НУРУ́ЛЛИН Ибраһим Зиннәт улы (18.04.1923, Самара губернасының Мәләкәс өязе (хәзер Ульяновск өлкәсе) Парау авылы – 01.07.1995, Казан), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы, публицист, филология фәннәре докторы (1968), профессор (1970), ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге (1982), ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Газ Исхакый исемендәге бүләге (1992) лауреаты.

Әбдери җидееллык мәктәбеннән соң (1937), сигезенче сыйныфны Мәләкәс урта мәктәбендә укый. 1938–1941 елларда Казандагы мех техникумында белем ала. Казан университетының тарих-филология факультетын (1950), шунда ук аспирантура (1953) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында каты яраланып кайтканнан соң, 1943–1945 елларда Парау авылы мәктәбендә укытучы булып эшли. 1950–1990 елларда — Казан университетында: 1970 елдан — профессор, 1978 елдан — рус һәм чит ил әдәбиятлары кафедрасында профессор-консультант хезмәтендә.

И.Нуруллин әдәбиятка прозаик-хикәяче буларак килеп керә. Парау мәктәбендә эшләгән вакытта «Совет әдәбияты» журналында аның «Ана тойгылары», «Рәхмәтулла абзый», «Кунакта» исемле беренче иҗат тәҗрибәләре басылып чыга. Университетта укыганда ук аны Габдулла Тукай иҗаты, аеруча хезмәтләрендәге әдәби тәнкыйть, эстетика, рус әдәбияты мәсьәләләре кызыксындыра башлый. Аның әлеге темаларны яктырткан «Тукайның әдәби пародияләре» (1948), «Тукай тәнкыйтендә реализм һәм типиклык мәсьәләләре» (1953), «Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты» (1955) хезмәтләре дөнья күрә. Шулай ук Фатих Әмирхан, Шәриф Камал кебек язучыларның иҗатларына, татар әдәбияты тарихының, агымдагы әдәби хәрәкәтнең аерым мәсьәләләренә караган мәкаләләре белән 1950 еллар башында ул үзен киң мәгълүматлы, мөстәкыйль фикерле һәм принципиаль карашлы әдәбиятчы-тәнкыйтьче итеп таныта. Соңыннан аның бу төр хезмәтләре, бергә тупланып, «Тукай эстетикасы турында мәкаләләр» (1954), «Шәриф Камал иҗаты» (1963), «Образлар дөньясында» (1964) исемле җыентыкларында урын ала.

20 йөзнең 60–70 нче елларында И.Нуруллин — татар әдәбияты тарихында аеруча зур урын тоткан галим һәм тәнкыйтьче. Эзләнүләрен дәвам иттереп, ул татар әдәбиятында иҗат ысуллары һәм әдәби юнәлешләр, тәнкыйди реализм методының туу һәм үсү үзенчәлекләре турында кызыклы күзәтүләргә, дәлилле теоретик гомумиләштерүләргә нигезләнгән китаплар яза. Аның хезмәтләре 20 йөз башы һәм совет чоры татар әдәбиятына, иҗади алымнар теориясенә, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Ибраһим Гази, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники һ.б. иҗатына карый. Язучы шәхесен һәм аның иҗат процессының асылын ачу И.Нуруллин хезмәтләренең төп темасын тәшкил

итә. Татар әдәбиятының күренекле вәкилләренә багышланган «Тукай Петербургта» (1965), «Аның йолдызы» (1973) пьесалары; әдәби-биографик характердагы «Габдулла Тукай» (1977), «Фатих Әмирхан» (1988) китаплары авторы. Гаяз Исхакый мирасын татар халкына кайтаруга зур өлеш кертә. Ул шулай ук татар әдәбияты тарихына, әдәбият белеме һәм әдәбият теориясенә караган хезмәтләр, методик кулланмалар бастырып чыгара («20 нче йөз башы татар әдәбияты», 1966; «Реализм турында мәкаләләр», 1974; «Әдәбият теориясе», 1977 һ.б.). Бер үк вакытта галим җанлы әдәби хәрәкәтне дә күз уңыннан төшерми, язучылык осталыгына бәйле мәсьәләләрне күтәргән күпсанлы тәнкыйть мәкаләләре, яңа басылып чыккан әдәби әсәрләрне анализлап язган бәяләмәләре белән матбугатта даими рәвештә катнашып килә.



И.З.Нуруллин

Үзенең хезмәтләрендә 19 йөз ахыры һәм 20 йөз башы әдәбиятындагы уңай идея-эстетик традицияләрнең, татар халык иҗаты һәм рус классик әдәбиятының хәлиткеч роль уйнаганлыгын күрсәтә. Каюм Насыйри иҗаты турындагы идея-эстетик карашларын иҗтимагый хәрәкәт, мохит, яшәү шартлары, мәгърифәтченең күпкырлы эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә чагылдыра. Галим шулай ук шул чорның әдәби-тәнкыйть принциплары турында да сүз ала. Аның фикеренчә, К.Насыйри тәнкыйди реализм принципларын гамәли рәвештә тормышка ашыру белән бергә әлеге иҗат юнәлешенә карата үз фикерләрен дә әйтә башлый. К.Насыйриның, шәрекъ стиленнән арына барып, әкренләп рус мәдәнияте тәҗрибәсенә йөз тотуын билгеләп үтә. Шул ук вакытта мәгърифәтченең Габдулла Тукайга кадәр үк халыклар арасындагы тарихи берлеккә, уртаклыкка игътибар итүен искәртә, аның «Россия кешесе (ягъни руслар) мөселманнар белән бер җирдә торган һәм бер җирдә үскән, бер икмәкне ашап үскәнлекләре сәбәпле, бу ике халык бер-берсенең гадәтен вә мөгамәләсен яхшы беләләр» дигән сүзләренә игътибар бирә. Мәгърифәтченең «Без Россия кешесе» дигән фикеренең Г.Тукайда да дәвам иттерелүенә басым ясый: «Рус җирендә без әсәрле, эзле без, / Тарихында бер дә тапсыз көзге без. / Рус белән тормыш кичердек сайрашып, / Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып («Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмитләре»).

И.Нуруллин «XX йөз башы татар әдәбияты: лекцияләр курсы» уку әсбабында, К.Насыйри хезмәтләренә таянып жанрлар мәсьәләсен тикшергәндә, болай дип яза: «Мәсәл исә XIX йөз татар әдәбиятында яратып кулланылган жанрларның берсе булды. Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның «Җәваһирел хикәят», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» җыентыкларында без гаять күп тәрҗемә мәсәл табабыз. Бу шулай ук очраклы күренеш түгел иде. XIX йөз татар мәгърифәтчеләренең дә әдәбият һәм сәнгатькә педагогик күзлектән карауларына, әдәбиятны әхлак төзәтү чарасы итеп санауларына бәйләнгән иде ул. Цитаталар белән мавыкмастан, Каюм Насыйриның җыр турындагы сүзләрен генә искә төшерик. «Фәһемне (уй-фикер) саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, җәбенне (йөрәксез, куркак) бәһадирландырыр, сараннны юмартландырыр».

1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Тукай иҗаты. Казан, 1964; Тукай турында хикәяләр. Казан, 1971; Габдулла Тукай. Казан, 1979; Тормыш һәм сәнгать чынлыгы: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан, 1983; Фатих Әмирхан. Казан, 1988; Путь к зрелости: о зарождении и развитии критического реализма в татарской литературе. Казань, 1971.

Әд.: Ибраһим Нуруллин: Истәлекләр. Казан, 2008; Нуруллина Р. Томаннарга еллар күмелде. Казан, 2003; Шәйдуллин Р.В. Якташыбыз Ибраһим Нуруллинга — 100 ел // Өмет, 2023. 10 май; Ибрагим Нуруллин в воспоминаниях. Казань, 2013; Мустафин Р. Проза литературоведа // Дружба народов. 1972. № 8; Нуруллина Р.М. Ибрагим Зиннатович Нуруллин. 1923–1995. Казань, 2000.

Р.В.Шәйдуллин.

О

«ОБРАЗЦЫ́ НАРО́ДНОЙ ЛИТЕРАТУРЫ́ КАЗА́НСКИХ ТАТА́Р» («Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре»), Каюм Насыйриның рус телендә язылган мәкаләсе. Ул беренче тапкыр 1896 елда «*Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*»ндә басыла. Шәркыятьче галим Н.Ф.*Катанов* аңа язган кереш өлешендә түбәндәгечә бәяләмә бирә: «Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә хакыйкый әгъза Габделкаюм Насыйров тарафыннан 28 табышмак, 243 мәкаль һәм 145 җырны үз эченә алган мәкаләләр тәкъдим ителә. Казан татарлары арасында халык иҗаты ядкәрләрен үзеннән элгәрерәк җыючылар булуга карамастан, Насыйров әфәнде беренче булып биниһая күп мәкаль һәм җыр тәкъдим итте. Әлеге материаллар Насыйров әфәнденең халыкның көнкүрешен һәм телен яхшы белүенә дәлил булып тора». Үзеннән элгәреләр дигәндә, Н.Ф.Катанов мажар (венгр) галиме Габор Балинтның «Kazáni-tatár nyelvtanulmányok. I. Fuzet. Kazáni-tatár szövegek» (1875), тарихчы һәм филолог Габделгалләм Фәезхановның «Хикәят вә мәкаләт» (1890), педагог Габдүш Баһаповның «Үзе-үзедин өйрәткеч татарлар урысча һәм урыслар татарча сөйләшергә» (1892), телче һәм фольклорчы Мөхәммәтшакир Салиховның «Табышмаклар һәм мәкальләр» (1880) басмаларын күздә тота.

Тупланган материаллар татар һәм рус телләрендә түбәндәге бүленештә бирелә: Табышмак (Загадки татарские); Кара халык сүзләре (Народные пословицы); Моңаеп җырлаган сүзләр (Унылые песни); Мактап җырлаган сүзләр (Хвалебные песни); Кавышырга мөштак булып җырлаган сүзләр; Үпкәләп җырлаган сүзләр (Песни, выражающие досаду); Фиракъ сүзләре (Песни разлуки); Гыйшык җырлары (Песни любви) һ.б.

Материаллар, бераз кыскартылып, Каюм Насыйриның «Сайланма әсәрләр»ендә (1945, 1953, 1956), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең беренче томында (1974), дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең өченче томында (2005) татар телендә урнаштырыла.

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; шул ук. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953, 1956; шул ук. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1974. 1 т.; шул ук. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2005. 3 т.; шул ук. Образцы народной литературы казанских татар // Изввестие Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Казань, 1896. Т. XIII, вып. 5.

Әд.: Гали М. Каюм Насыйриның рус матбугатында басылган әсәрләре // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; Гаффар Ә. Рус матбугатында Каюм Насыйри // Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга / Ред. Һәйят. Казан, 1922.

Р.Ф.Исламов.

ОЛЫ́ АЧАСЫ́Р, татар авылы. Буа елгасының сул кушылдыгы буенда, Яшел Үзән шәһәреннән 25 км көньяк-көнбатыштарак урнашкан.

Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Әлеге авыл Каюм Насыйри тарафыннан мондый сүзләр белән сурәтләнә: «Бу Ачасыр авылының иң әүвәл утырган кешенең исеме кем икәне мәгълүм түгел. Әмма риваятьләр гуаһылык бирәдер, анда әүвәл бер чуваш килеп утырган бер ятим бала белән. Ул вакыт Ачасыр урыны урман булган. Ул кеше шул ятим бала белән килеп, баласын бишеге белән имән ботагына асып тирбәткән. «Йокла, атасыз, йокла!» дип үз теленчә. Шуннан Ачасыр дип исем калгандыр. Ачасыр дигән чуваш сүзе булырга кирәк. Ача дип атаны әйтәләр икән, сыр дигәне хәрфе нәфидер. Ачасыр атасыз дигән сүз буладыр. Ягъни бер атасыз ялгыз чуваш булгандыр. Шуннан соң җыелып, зур авыл булгандыр. Башка авыл халкына караганда, бу Ачасыр кешеләренең кыяфәтендә, тереклегендә һәм телләрендә бернәрсә аермасы бар. Ләкин Ачасырның тарихы кай заманнан икәне мәгълүм булганы юк. Янә Ачасырга Түбән Шырданнан барып утырган кешеләр дә бар икән... Хәзер дә бу Ачасыр авылы байтак зур авыл. Иген-тару аларда яхшы буладыр; хосусән бодайны бик игәләр. Әхмәт хәзрәт мәрхүм Ачасыр бодае дип мактый торган иде. Вакыйган, Ачасырлар иген эшен бик оста эшлиләр...»

1920 елга кадәр авыл Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостена керә. 1920 елдан — ТАССРның Зөя кантонында. 1927 елның 14 февраленнән — Норлат, 1963 елның 1 февраленнән — Яшел Үзән районында (хәзер — Олы Ачасыр авыл җирлеге үзәге).

Тарихчы Д.А.Корсаковның мәгълүматларына караганда, Казан губернасының Олы Ачасыр авылында 1771–1773 елларда 415 йомышлы, 66 керәшен татар ир-аты яши. 1859 елда — 1778, 1897 — 3034, 1908 — 3413, 2021 елда 573 кеше яши.

18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крестьяннары (элекке ясаклы татарлар, 18 йөздә йомышлыларга күчерелә) катлавына керә, 14% ка якыны чукындырылган була. 1930 елга кадәр халкының төп шөгыльләре — игенчелек һәм терлекчелек. Авыл җәмәгатенең имана җире 2389 дисәтинә тәшкил итә. 3 йон-тукыма ману заводы, 8 тегермән, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли.



Олы Ачасыр авылы. Мәчет.

1874 елда беренче мәхәллә мәчете үзгәртеп салына. 1832 елда икенче мәхәллә оештырыла (ике мәхәлләнең дә мәчетләре 1930 елларда ябыла). 20 йөз башында 2 мәктәп (җәдиди һәм кадими ысуллы, 1909 елда аларда 60 ир бала һәм 45 кыз бала укый) була.

1918 елда башлангыч мәктәп ачыла, ул 1935 елда — җидееллык, 1956 елда урта мәктәп итеп үзгәртелә (2015 елдан — тулы булмаган урта мәктәп). 1986 елда мәктәп каршында Г.Ә.Абзалина җитәкчелегендә туган якны өйрәнү музее оештырыла. Хәзерге вакытта «Гөлчәчәк» балалар бакчасы (1946 елдан), мәдәният йорты, китапханә, фельдшер-акушерлык пункты, ветеринария участогы, мәчет (1991 елдан), мәдрәсә (1993 елдан) эшли. 1997 елда авылда Каюм Насыйри исемен-

дәге *Архитектура-этнография комплексы* ачыла (оештыручысы — Р.Ә.Абзалина).

Авыл чишмәләргә бай. Мул сулы «Бәйрәш чишмәсе»нә нисбәтле риваять тә бар. Исеме К.Насыйриның ерак бабасы Бираш (Бәйрәш) белән бәйле. Чишмә Кече Шырдан ягына таба сузылган тау итәгеннән агып чыга. К.Насыйри: «Болгардан Шырдан җиренә күчеп килгән алты кешенең берсе үзенең ике углы белән килгән. Әмма, үзенең исеме мәгълүм булып калмаган. Бер углы Бираш (Бәйрәш), икенче углы Атна Хуҗа дигән кешеләр икән.



Олы Ачасыр авылы. Бәйрәш чишмәсе.


Хәзер дә Иске йортта Атна Хуҗа дигән чишмә бар; шул Атна Хуҗа казыган чишмәдер. Әмма Бираш белән Атна Хуҗаның аталары монда күчеп килгәч, озак тормаган, хаҗга китеп, шунда вафат булып калган. Янә бер чишмә бардыр: Бираш Кизләве дип йөртәләр; хәзер дә ул Кизләү Ачасыр кырында калгандыр. Шул Бираш баба казыган кизләү дип риваять кылалар, — дип яза. — Ачасырның көньягында тагын бер истәлекле чишмә — «Күҗәмкә» чишмәсе ага. Чишмә авылның Күҗәмкә урамына карый. Ачасыр янында хәзер дә бер «Күҗәмкә» дигән кечкенә авыл бар. Зөя янындагы Күҗәмкә шунда күчкәндер», — дип фаразлый.

Әд.: Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан. Казан, 1997; Җәбәлстан. Ачык сырт. Олы Ачасыр авылы тарихыннан сәхифәләр. Йошкар-Ола, 2021; Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. 3 том. Казан, 2005; Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII веке, изданный под редакцией Д.А.Корсакова // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Казань, 1908.

Ф.Г.Камальтдинова.

«ОСУЛЕ́ ҖӘГЪРӘФИЯ́» («Осуле җәгърәфияи кәбир»), өч томлы география китабы. Каюм Насыйри тарафыннан 1873–1877 елларда языла һәм 1894, 1898, 1899 елларда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә.

«Осуле җәгърәфияи кәбир»нең беренче китабы — Азия (1894), икенчесе — Африка (1898) кыйтгалары, өченчесе Гарәбстан, Сүрия һәм Гыйрак (1899) илләре турында. Әлеге китапларны язганда К.Насыйри гарәп, фарсы, госманлы, рус телләрендәге гео-


الجلد الثانى
من
اصول جغرافياى كبير
آفريقه قطعه‌سى
تاشان
КАЗАНЬ.
Типо-литография Императорскаго Университета.
1898.

К.Насыйри. «Осуле җәгърәфияи кәбир. Әл-җилди әүвәл. Азия кыйтгасы». Казан, 1898.

графия тарихларыннан файдалана. Беренче китабының тышында «Рофга әфәндедән — «Тәгърибате шафия», «Җиһаннамәи» — Кятиб Чәләби, «Җәгърәфияи кәбир» — Әхмәд Хәмиди, «Хөсне мохазара» — имам Сойути, «Төхфәте әл-кәрам» — имам Сойути вә кәзалик (тагын) мәмләкәтемездә рус телендә табыг кылынмыш: Разин-Ольхин, Ободовский, Усов, Корнил-Даниил вә гайреләр», дип, авторларын санап китә.

Томнарда югарыда әйтеп үтелгән кыйтгаларның, илләрнең географиясе, алардагы табигать күренешләре, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, сулары, шәһәрләре, кешеләренең тормыш-көнкүреш шартлары, сәүдә системасы, аерым хөкемдарлары, Ислам диненең таралуы, Кәгъбәнең төзелүе һ.б. турында бәян ителә.

Кереш өлеше Каюм Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1953, 1956), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томына (1975), текстның берничә өлешен өстәп, дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең 3 нче томына да (2005) урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Осуле җәгърәфияи кәбир. Әл-җилди әүвәл. Азия кыйтгасы. Казан, 1898; шул ук. Осуле җәгърәфияи кәбир. Әл-җилди әс-сани. Африка кыйтгасы. Казан, 1898; шул ук. Осуле җәгърәфияи кәбир. Әл-җилди әс-салис. Оусаф җәзирәт әл-гарәб, ягъни Гарәбстан, Шам вә Гыйрак мәмләкәтләре хакында җәгърәфия фәнендә тәварих кадимәсене мөштәмил бер рисаләдер. Казан, 1899.

Әд.: Катанов Н. Усули джаграфия-и кабир (основания географии). Казань, 1898. Типо-литогр. ун-та. 200 стр. // Деятель. 1898. № 12; шул ук. Усули джаграфия-и кебир (основы большой географии). Казань, 1899. Типо-литогр. ун-та. 138 стр. // Деятель. 1900. № 10.

Р.Ф.Исламов.

П

ПА́РСИН Мөхәммәт Зариф улы (09.03.1899, Казан губернасының Казан өязе (хәзер Татарстанның Биектау районы) Олыяз авылы – 08.04.1963, Яшел Үзән шәһәре), журналист, публицист, әдәбият һәм театр тәнкыйтьчесе.

Укытучылар курсын тәмамлаганнан соң, Казан өязе мәктәпләрендә укыта, үзешчән театрлар оештыруда катнаша. Комсомол ячейкалары оештыру буенча эшләр алып бара, 1920 елның сентябрендә Татарстан комсомолының 1 нче өлкә конференциясендә РКСМ өлкә комитетына сайлана. 1919 елда «Эш», «Кызыл Армия» газеталары белән хезмәттәшлек итә башлый. 1920 елларда Мәскәү журналистика институтында белем ала, комсомол басмалары: «Кызыл яшьләр» (Казан) газетасында, «Кызыл Шәрекъ яшьләре» (Казан), «Яшь эшче» (Мәскәү) журналларында мөхәррир булып эшли. 1925 елдан — «Кызыл Татарстан» газетасы хәбәрчесе. «Крестьян газеты»нда, «Эшче» газетасында, «Кызыл Шәрекъ», «Чаян» журналлары һ.б.да сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы үсеше турында яза. Татар театрына багышланган, татар әдәбияты һәм сәнгате үсешен яктырткан мәкаләләр, спектакльләргә бәяләмәләр авторы. «Театр мәҗмугасы: Татар театрының 20 еллык бәйрәме» (1925), «Татар театры. 1906–1926» (1926) җыентыкларын төзүче.



М.З.Парсин

1925 елның 15 февралендә «Кызыл Татарстан» газетасында Татар дәүләт театрында *Гыйльми үзәк* тарафыннан Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулуга багышланган зур җыелыш үткәреләчәге хакында игълан басыла. Җыелышта Татарстан Җөмһүриятe хөкүмәтенең мәгърифәтче шәхесен олылауга караган эшләре тыңланылачагы белдерелә. Анда гыйльми әдәбият ияләренең катнашулары, матбугатка яңа язмалар бирелү турында, татар теле һәм әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән К.Насыйриның хезмәтләрен, әсәрләрен һәм тарихи ролен фәнни күзлектән тикшерү рәвешендә булачагы әйтелә. Әлеге чарада М.Парсин да «Насыйриның биографиясе» дигән темага доклад белән чыгыш ясый. Ул мәгърифәтче галимнең тормыш юлын һәм иҗат эшчәнлеген әтрафлы яктырта.

1941 елның 7 октябрендә, советка каршы милли оешмалар эшчәнлегендә катнашуда гаепләнеп, кулга алына (кулга алынганчы «Красный дорож-

ник» артелендә эшли); 1942 елда Красноярск өлкәсенә 5 елга сөргенгә озатыла; 1948 елда кайтарыла; 1956 елда аклана. 1949 елдан Яшел Үзән шәһәрендә яши.

Хезм.: Каюм Насыйриның туганына йөз ел тула // Кызыл Татарстан. 1925. 8 февраль; Каюм Насыйриның тууына йөз ел тулу уңае белән зур җыелыш! // Кызыл Татарстан. 1925. 15 февраль.

Әсәр.: Ураза бәйрәмендә: Комедия 2 пәрдәдә. Казан, 1926.

Л.М.Айнетдинова.

ПЕРО́В И.С. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́, Казанда. 1871 елда Казан цехчысы Иван Семёнович Перов тарафыннан ачыла. Соңгы хуҗасы — М.А.Семёнов (1911 елдан). 1916 елга кадәр эшли. Шәһәрдәге иң эре полиграфия предприятиеләренең берсенә әверелә. 1870 елларда анда — 10, 1888 елда — 17, 1899 елда — 40, 1915 елда 50 кеше эшли. Тәүге продукциясен рус наширләре заказлары буенча басылган эстамплар тәшкил итә.

1879–1910 елларда 890 мең тираж белән 67 исемдә татар басмасы нәшер ителә. 20 йөз башыннан төп продукциясе газеталардан һәм китаплардан гыйбарәт була. Казан университеты профессорлары һәм табибларының фәнни хезмәтләре, иҗтимагый оешмалар һәм үзидарә органнарының хисаплары, православиегә караган дини әдәбият дөнья күрә.

1883 елда Каюм Насыйриның куй елына багышланган 48 битле календаре, 1898 елда «Кырык бакча» әсәре басылып чыга.

1905 елдан соң Казан карагруһчыларының газеталары һәм листовкалары бастырыла (И.С.Перов уң оешмаларның гаять актив эшлеклесе була). 1910 елдан соң «Камско-Волжская речь» либераль газетасы чыгарыла башлый.

Әд.: Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. Казань, 2005; Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. Казань, 1974.

И.Х.Хәлиуллин.

ПЕЧӘ́Н БАЗАРЫ́, 18 йөздә – 1930 еллар башында Казан шәһәренең Иске Татар бистәсендәге сәүдә, иҗтимагый һәм мәдәни тормыш үзәге. Шәрекъ базарына хас корылмалары булган сәүдә урыны. Атамасы анда сатылган товарларның берсенә нисбәтле. Мәйданы озынча турыпочмаклык рәвешендә булып, чикләре буйлап татар сәнәгатьчеләренең һәм сәүдәгәрләренең европача төзелгән аерым йортлары һәм утарлары, табыш йортлары, кунакханә номерлары, кибетләр һәм мунчалар тезелгән.



Печән базары. XIX йөз ахыры.

Каюм Насыйриның Казандагы тормышы Печән базары тирәсе белән тыгыз бәйле. Ул шуннан ерак түгел Сәгъди Яхин өендә, Сая Ибрай номерларында, Мокрый урамындагы кабакның икенче катында урнашкан фатирда, икенче гильдия сәүдәгәрләр Шаһиәхмәт Салихов һәм Гайса хаҗи Мусин (кара: *Мусин Гайса йорты*), беренче гильдия сәүдәгәр Сөләйман *Аитов*, абыйсы Габделхәйнең улы Габделмән Казанский (кара: *Насыйрилар нәселе*), Чыршы Габди, туганы Мөхәммәтбәдигъ *Хөсәенов* йортларында төрле елларда яшәгән.

Әд.: Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVIII гасыр ахыры — XX гасыр башы). Казан, 1995; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана, 2001. Т.1–2; Республика Татарстан: памятники истории и культуры. Казань, 1993; Список посёлков, слобод и улиц, входящих в черту г. Казани // Вся Казань: Справочная книга по городу Казани. Казань, 1940.

И.Х.Хәлиуллин.

ПЕЧӘ́Н БАЗАРЫ́ УРАМЫ́ (Аркылы Печән базары урамы), Казанның Иске Татар бистәсендәге иң борынгы тарихи урамнарның берсе; 1938 елдан — Париж Коммунасы урамы, Вахитов районында урнашкан.

18 йөз ахырында атлар һәм печән сату базарлары эшләгән шәһәр сәүдә мәйданы белән бер үк вакытта формалаша башлый. 1768 елгы даими план буенча корылмалар төзелгәннән соң, Татар урамы дип тә атала. 18–19 йөзләр чигендә андагы базар шәркый рәвештәге эре сәүдә үзәгенә әверелә. Татарлар аның көньяк һәм көнчыгыш тарафларында яшиләр. Урам, мәйдан кебек үк, аларның икътисади, мәдәни һәм иҗтимагый тормышы белән тыгыз бәйләнгән. *Печән базары* корпусларында сәүдә кибетләре эшләгән. Аркылы Печән базары урамында мәгърифәтче галим Каюм Насыйри туганы Мөхәммәтбәдигь *Хөсәенов* йортында 1902 елга — вафатына кадәр яши. Әлеге йорт, 1979 елда янганнан соң, 1991–1995 елларда тулысынча торгызыла, һәм анда 2002 елда *Каюм Насыйри музее* ачыла.



Печән базары урамы. XIX йөз ахыры.

Әд.: Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре. Казан, 1995; Казань: исторические районы, слободы, улицы, площади и парки: иллюстрированный энциклопедический справочник. Казань, 2021. Кн.1.

И.Х.Хәлиуллин.

«ПОВЕ́РЬЯ И ОБРЯ́ДЫ КАЗА́НСКИХ ТАТА́Р, ОБРАЗОВА́ВШИЕСЯ МИ́МО ВЛИЯ́НИЯ НА ЖИЗНЬ ИХ СУННИ́ТСКОГО МАГОМЕТА́НСТВА» («Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр»), Каюм Насыйриның рус телендә язылган мәкаләсе. Ул беренче мәртәбә 1880 елда «*Император рус география җәмгыяте язмалары*»нда дөнья күрә. Петербург шәркыятьче галиме В.В.*Григорьев* аңа язган кереш мәкаләсендә түбәндәге сүзләрне китерә: «Казан университетында алган Европа белеме аны акыл ягыннан шундый югарылыкка күтәргән ки, ул безнең мөселманнар арасында исламга объектив караучыларның беренчесе... Аның фәнни тикшеренүләренең мөселманлыкны пропагандалау юнәлешендә кулланылу ихтималы мәсьәләсендә шикләнергә бернинди дә сәбәп юк». Бу хезмәтне ни өчен һәм ничек язуы турында К.Насыйри болай аңлата: «Бу әмәл белән рус укучысын татар хикәяләре вә аның шулар белән бергә туган ырымнары белән таныштырырга телим. Аларда иске татар игътикадатының эзләре хәзер дә бар вә алар

үзләре дә татарлыкны күрсәтеп тораллар. Татар хикәяләре хакында булган тикшерүләремне балалык вакытында ишеткән нәрсәләремнән, үземнең соңыннан татарлардан сүзләшеп белгән нәрсәләремнән алып язам. Соңгылары да боларга бары фәнни яктан карарга өйрәнгәч кенә җыйган нәрсәләрем».

Мәкаләдә башта *ышанулар* китерелә. К.Насыйри аларны ике төркемгә: а) судагы һәм б) җир өстендә яши торган мәгъбүдләргә (затлар) бүлә. Беренчесенә — су бабасы, су иясе, су анасы, юха, икенчесенә убыр, албасты, өрәк, бичура, өй иясе, абзар иясе, чәчәк анасы, чәчәк иясе, шүрәле, җен һәм дию пәрие керә. Аларның һәрберсенә аңлатма бирелә. Мәсәлән, су бабасы турында: «Татарлар, су бабасы исеме белән суда яши торган (мин җыйган хикәяләрдә бары күлдә генә яшиләр) су патшасы, су мәгъбүден атыйлар. Һичбер хикәя аның судан чыгып йөрүе, кешеләр белән мөнәсәбәткә керүләре турысында сөйләми; аның төрле әмерләрен җиренә җиткерер өчен куелган хезмәткәре бар. Ул аның әмерләрен җиренә җиткерә вә кушкан эшләрен эшләп тора...», — дип яза.

Аннан соң шундый әүһами (хыяллардагы) юраулар китерелә. Татарлар алда булачакны белү өчен йорт хайваннарына (мәче, эт, тычкан, ат), йорт һәм аның тирәсендә яши торган кошларга (тавык, карга, саескан, чәүкә), үз тәнендәге әгъзаларга (борын, ирен, кул, колак) нисбәтле бага. Мәсәлән, «Уң колак кычытса, татар «җылы булачак» дип белә; сул колак кычытса, салкын, кояш колаклы булып чыкса, салкынга».

Ырымнар һәм имләүләр турында сүз алып барып, К.Насыйри: «Казан татарлары ислам дине кушкан гыйбадәтләрдән, догалардан башка мәҗүсилектән калган ырым вә имләүләр ясыйлар. Алар түбәндә язылачак авырулардан котылуны өмет итәләр: вафа-холера, хайван үләте, чәчәк, күз тию, эч авырту, бирән зәхмәте, бизгәк, котырган эт тешләп котыру, эт имчәге», — дип яза. Әйтик, балалардагы чәчәк авыруын дәвалау турында шундый мәгълүмат китерә: «Баланың чәчәге йиңгел үтсен өчен фәкыйрьләргә ак үрдәк яки ак каз сәдака итеп бирәләр дә, бала терелә башлагач, «Чәчәк боткасы» исемле ботка пешереп ашыйлар. Болай эшләмәсәк, чәчәк авыр була, диләр».

Хезмәт беренче мәртәбә, татар теленә тәрҗемә ителеп, гарәп хәрефләрендә К.Насыйриның вафатына егерме ел тулу уңаеннан нәшер ителгән «Каюм Насыйри мәҗмугасы»нда (1922), соңыннан бераз кыскартылып, рус графикасында «Сайланма әсәрләр»ендә (1953, 1956), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томында (1975), дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең 3 нче томында (2005) урнаштырыла; рус телендә «Император рус география җәмгыяте язмалары»нда 1880 елда дөнья күргән оригинал язмасы «*Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык*»та 2007 елда бастырыла.

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1975. 2 нче т.; шул ук. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2005. 3 нче т.; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017. Насыри К. Поверья и обряды казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки Императорского Русского Географического Общества по отделению этнографии. СПб., 1880. Т. 6.

Әд.: Гали М. Каюм Насыйриның рус матбугатында басылган әсәрләре // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945; Гаффар Ә. Рус матбугатында Каюм Насыйри // Каюм Насыйри мәҗмугасы. Ва-

фатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга / Ред. Һәйят. Казан, 1922.

Р.Ф.Исламов.

«ПО́ЛНЫЙ РУ́ССКО-ТАТА́РСКИЙ СЛОВА́РЬ» («Полный русско-татарский словарь, с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины» — «Рус хоруфе һәҗәс үзә мөрәттиб лөгать китабы» — «Рус хәрефләре белән төзелгән сүзләр китабы»),


ПОЛНЫЙ
РУССКО-ТАТАРСКІЙ
СЛОВАРЬ,
СЪ
ДОПОЛНЕНІЕМЪ ИЗЪ ИНОСТРАННЫХЪ СЛОВЪ,
УПОТРЕБЛЯЕМЫХЪ ВЪ РУССКОМЪ ЯЗЫКѢ
КАКЪ НАУЧНЫЕ ТЕРМЕНА.
Составилъ
Абдулъ-Кеюмъ бинъ Абду-Н-насыри-Н-насыри-и-ль-Казани.
(Изданіе второе, книгопродавца И. Н. Шамсутдинова.)
КАЗАНЬ.
Типо-литографія Императорскаго Университета.
1904.

К.Насыри. «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины». Казань, 1892.

рус телен өйрәнү өчен кулланма. Кәюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1892 елда Казан университеты басмаханәсендә бастырыла. Китапның титул битендә сүзләрнең мәгънәләренә һәм чыганакларына аңлатмалар бирү турында шулай язылган: «Рус кәлимәләренең (сүзләренең) мәгънәсе тәфсыйлан (җентекләп) бәян кылынып, хәреф җәрле (предлог һәм приставка) фигыльләрдә вә дәхи һәрбер хәрфе җәрненең мәүзугы ләһ мәгънәләре (үзенә хас мәгънәләре) тәфсыйлан бәян кылынды — янә рус кәлимәләреннән магада [башка] рус телендә мөстәгъмәл булгучы [кулланыла торган] әҗнәби лөгатьләргә [чит тел сүзе] рус телендә фөнүне шәтта [төрле фәннәр] истыйлахлары [терминнары] күбрәк әҗнәби лөгатьләрдер — зикер кылынды».

Хезмәттә, автор үзе язганча, 20 мең чамасы рус сүзе кертелгән. Алар, шул чор рус орфографиясе буенча язылып, рус алфавиты тәртибендә урнаштырылган. Рус сүзләренең тәрҗемәсендә шул чордагы татар әдәби телендә кулланылган татар лексикасыннан файдалану белән беррәттән гарәп, фарсы, төрки сүзләр һәм тәгъбирләр дә иркен кулланылган. Шуңа күрә саф татар сүзләреннән генә торган тәрҗемәләр белән бергә татар, гарәп, фарсы сүзләре аралаштырылып бирелгән тәрҗемәләр, фәкать гарәп, фарсы сүзләреннән генә торган тәрҗемәләр дә очрый. Рус сүзләренең тәрҗемәсе буларак бирелгән гарәп, фарсы сүзләре киң кулланылмаган яки татарча тәрҗемәләре табылмаган очракта, җәяләр эчендә аларның татарча аңлатмалары язылган. Бер үк сүзнең сөйләмдә төрле мәгънә белдерүен аныклап күрсәтергә кирәк булганда, аларның төп мәгънәләре белән бергә өстәмә мәгънәләре дә аерым мисаллар ярдәмендә күрсәтелгән.

Әлеге сүзлекнең әһәмияте турында Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфетдин әл-Кустрамави «Шура» журналында (1912) бастырган «Габделкаюм ән-Насыйри хәзрәтләре тәрҗемәи хәленә гаид» мәкаләсендә болай дип яза: «Бу соңгы китапны күп шәкертләрнең кулларыннан төшермичә истигъмаль вә истифадә итүләре [файдаланулары һәм кулланулары] күренәдер. Занымча [уемча], заман үтүе тәэсир итмәгән вә әһәмияте кимемәгән китап улып, Габ-

делкаюм әфәнде ялыңыз ошбу әсәре илә дә бу көндәге шәкертләргә файда китерә вә мөгаллимлек итәдер».

Сүзлек кабат 1904 елда, ягъни К.Насыйриның вафатыннан соң Казан университеты басмаханәсендә Исмәгыйль Шәмсетдинов акчасына нәшер ителә.

Чыг.: Насыйри К. Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины. Казань, 1892.

Әд.: Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфетдин әл-Кустрамави. Габделкаюм ән-Насыйри хәзрәтләре тәрҗемәи хәленә гаид // Шура. 1912. № 8; Хангильдин В. Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Р.Ф.Исламов.

ПОЛЯКО́В Пётр Александрович (19 йөзнең 2 нче яртысы – 20 йөз башы), шәркыятьче галим, фольклорчы, педагог. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (1891), Сәмәрканд археология, тарих һәм этнография сөючеләр түгәрәге (1908) әгъзасы.

19–20 йөзләр чикләрендә Җидесу өлкәсенең Верный шәһәрендәге (хәзер Алма-Ата, Казакъстан) гимназиядә укыта.

Хезмәтләре ислам диненең төрки халыклар, монголлар, индуслар һәм кытайлар арасында таралуы мәсьәләләренә, Ягъкуб улы Йосыфка, татар әкиятләрен өйрәнүгә карый. Ул 1900 елда Каюм Насыйри белән берлектә «*Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*»нең 16 нчы томында һәм аерым китап рәвешендә «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» хезмәтен бастырып чыгара. Анда К.Насыйри тарафыннан Казан губернасының Зөя өязе авылларында язып алынган 11 татар әкияте («Салам-торхан», «Юләр угыл», «Үги кыз», «Гөлнәзек», «Байдек», «Өч угыл», «Гакыллы угыл», «Төлке», «Мәче белән аю», «Аю белән төлке», «Сандугач белән бытбылдык») урнаштырылган, аларны Н.Ф.*Катанов* кириллица имлясында транскрипцияләгән, П.Поляков, рус теленә тәрҗемә итеп, башлыча рус халык әкиятләре («Кузьма Скоробогатый», «Бухтан Бухтанович», «Ванька Голый», «Иванушка-дурачок», «Морозко», «Падчерица», «Баба-яга», «Цыган», «Шабарша», «Иванко-медведко», «Мутонюшка»), удмурт әкияте («Иманай»), шулай ук исемнәре күрсәтелмәгән кыргыз әкиятләре белән чагыштырган.

Хезм.: Ислам среди тюрков, монголов, индусов и китайцев: [На основании кн.: Essai l'histoire de l'islamisme par R. Dozy. Leyde, 1879]. Казань, 1895; Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Казань, 1900. Т.XVIII, вып.4–6 (А.К. Насыров белән автордашлыкта); Снотолкователь, приписываемый мусульманами ветхозаветному патриарху Иосифу, сыну Иакова (Джагатайский текст, русская транскрипция и русский перевод). Казань, 1901.

Әд.: Хабибуллина Д.А. Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов в «Известиях Общества археологии, истории и этнографии» // История России и Татарстана: Итоги и перспективы энциклопедических исследований: Сборник статей итоговой научной конференции научных сотрудников Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ (г. Казань, 19 мая 2022 г.). Казань, 2022.

И.Х.Хәлиуллин.

ПОРТРЕТЛА́Р ҺӘМ БЮСТЛА́Р, Каюм Насыйригa нисбәтле сәнгать әсәрләре. Портрет — сынлы сәнгатьтә башлыча күренекле шәхеснең сурәтен тасвирлауга багышланган нәкышь, графика, скульптура жанрларының берсе, нигездә, әлеге жанрларда башкарылган әсәр, ягъни кеше яки кешеләр төркеменең фотографиядәге, сынлы сәнгатьтәге сурәте.

Казанда беренче фото җәмгыятьләре 1895 елда барлыкка килә, шәхси фотографлар исә 1851 еллардан эшли. Шулай булуга карамастан, Каюм Насыйриның үзе исән вакытта ясалган фоторәсеме дә, портреты да юк. Гомеренең сонгы елларында аның рәсемен ясарга дип, яисә фотога төшүен сорап килүчеләргә: «Рәсем алдырганым юк, <...> ач вакытымда хәлемне сорамадылар, хәзер соң инде», — дип, ризалык бирми. Рәссамнар К.Насыйриның портретын аны күргән-белгән кешеләр тасвирлавына таянып иҗат



Г.А.Арсланов. «Каюм Насыйри» портреты. 1920 еллар башы.



Б.М.Әлминов. «Каюм Насыйри» портреты. Автолитография. 1950.



Б.М.Әлминов. «Каюм Насыйри» портреты. Киндер, майлы буяу. 20 йөз урталары.



Ф.М.Михайлов. «Каюм Насыйри портреты». 1957.



З.И.Басыйров. «Каюм Насыйри». Картон, 20 йөз.



Ф.Р.Вәлиуллин. «Каюм Насыйри». Кәгазь, ретушь. 1991.



Э.Я.Зарипов.
«Каюм Насыйри».
Линогравюра. 1984.




Э.Я.Зарипов.
«Каюм Насыйри». Катыргы,
гуашь. 1990 еллар башы.



Ф.Р.Жумаева.
«Каюм Насыйри».
Графика. 2023.




К.Е.Максимов. «Каюм Насыйри дару үсемлекләрен өйрәнә».
Киндер, майлы буяу. 1960.



З.Ф.Гыймаев.
«Каюм Насыйри портреты».
Киндер, майлы буяу. 2001.



Ф.Г.Халиков.
«Каюм Насыйри».
Киндер, майлы буяу. 2005.



М.К.Мавровская.
«Каюм Насыйри һәм кечкенә Тукай».
Кәгазь, пастель. 20 йөз.



Р.М.Вахитов.
«Каюм Насыйри портреты». 2007.



Х.С.Кавиев.
«Каюм Насыйри».
Гипс. 1930 еллар.



С.С.Ахун.
«Каюм Насыйри».
Гипс.1941.



В.Ш.Шәрәфетдинов.
«Каюм Насыйри».
Гипс. 1967.



Н.И.Адылов.
«Каюм Насыйри».
Агач. 1988.




Х.Х.Миннегалиев.
«Каюм Насыйри: мәдрәсәдән дөньяви мәктәпкә». 2022.



Б.Урманче.
«Каюм Насыйри».
Гипс. 1970.



Н.И.Адылов.
«Каюм Насыйри».
Гипс. 1997.



В.В.Носов.
«Каюм Насыйри».
2000.




Б.Урманче.
«Каюм Насыйри».
Мәрмәр . 1970.



Р.Галиев.
«Каюм Насыйри».
Горельеф. 20 йөз.

итәләр. Галимнең беренче портрет-рәсемен (1920 еллар башы) рәссам Г.*Арсланов* ясый. Ул аны Г.*Рәхимнең* «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле» хезмәтендә тасвирланганча сурәтли. Монда галим фәкыйрь, мескен кыяфәтле кеше итеп ясалган була. Әлеге рәсемне К.Насыйриның 100 еллыгын үткәрү чарасында Ф.*Әмирхан* һәм башкалар кискен тәнкыйтьләп чыга. Һәм президиум яңа портрет ясатырга дигән карар чыгара. 1944 елда, мәгъри-



С.В.Царёв.
«Каюм Насыйри». График композиция. 2022.

фәтченең 120 еллыгы якынлашканда, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры М.*Гайнуллин* китап графикасы өлкәсендә әйдап баручы рәссамнарның берсе — Б.*Әлминовны* чакырып ала һәм аңа К.Насыйри портретын ясауны йөкли. Галимне күреп-белгән кешеләр белән очрашып, аларның истәлекләрен өйрәнгәннән соң, безгә таныш «Каюм Насыйри» портреты (1950) туа. Галимнең шәкертләре «Нәкъ үзе», — дип, рәссамның эшен хуплыйлар. Ул аны берничә вариантта: автолитография ысулы белән кәгазьдә, (1950), майлы буяулар белән киндердә (20 йөз урталары) ясый. Хәзерге вакытта К.Насыйригa багышланган сынлы сәнгать әсәрләре башлыча шушы портретка һәм замандашлары истәлекләренә нигезләнеп иҗат ителә.

К.Насыйригa багышланган портретларның авторлары: Ф.М.Михайлов («Каюм Насыйри портреты», 1957), К.Е.*Максимов* («Каюм Насыйри дару үсемлекләрен өйрәнә», киндер, майлы буяу, 1960), Ф.Р.*Вәлиуллин* («Каюм Насыйри», ретушь, 1991), М.К.Мавровская («Каюм Насыйри һәм кечкенә Тукай», кәгазь, пастель, 20 йөз), З.И.Басыйров («Каюм Насыйри», картон, 20 йөз), З.Ф.*Гыймаев* («Каюм Насыйри портреты», киндер, майлы буяу, 2001), Р.М.*Вахитов* («Каюм Насыйри портреты», 2007), Э.Я.*Зарипов* («Татар мәгърифәтчеләре» линогравюралар сериясеннән «Каюм Насыйри», 1984; «Каюм Насыйри», катыргы, гуашь, 1990 еллар башы), Ф.Г.*Халиков* («Каюм Насыйри», киндер, майлы буяу, 2005), М.Рәхимов («Мәгърифәтче-галим Каюм Насыйри үзенең туган авылы Югары Шырдан кешеләре арасында»), С.В.*Царёв* («Каюм Насыйри», график композиция, 2022), Ф.Р.Жумаева («Каюм Насыйри», графика, 2023).

К.Насыйриның кәгазьгә һәм киндергә төшерелгән портретлары белән беррәттән аның скульптур портретлары да эшләнә. Скульптур портретлары авторлары: Х.С.*Кавиев*, Б.*Урманче*, Н.И.*Адылов*, С.С.*Ахун*, В.Ш.*Шәрә-*

фетдинов, В.В.Носов (бюст Апас районы үзәгендә), Х.Х.Миннегалиев («Каюм Насыйри: мәдрәсәдән — дөньяви мәктәпкә» скульптур композициясе, Казан шәһәренең 80 нче мәктәбендә).

Әлеге рәссамнарның сынлы сәнгать әсәрләре төрле дәүләт оешмаларында, мәктәп, музейларда, шәхси коллекцияләрдә саклана.

Әд.: Хуҗиева Э. Каюм Насыйриның рәсеме турында риваять // Мәдәни җомга. 2025. № 4.

Ф.Г.Камальтдинова.

«ПРЕПОДАВА́НИЕ НА ТАТА́РСКОМ ЯЗЫКЕ́ В СИСТЕ́МЕ СРЕ́ДНЕГО И ВЫ́СШЕГО ОБРАЗОВА́НИЯ: ИСТО́РИЯ, СОВРЕМЕ́ННОСТЬ И ПЕРСПЕКТИ́ВЫ» («Урта һәм югары белем бирү системасында татар телендә укыту: тарих, заманчалык һәм алгарышлар»), конференция материаллары җыентыгы. Анда ТР Фәннәр академиясе Тарих институты тарафыннан 2015 елда Каюм Насыйриның тууына 190 ел тулу уңае белән уздырылган төбәк фәнни-гамәли конференциясенең татар һәм рус телләрендәге материаллары урнаштырылган. Төзүчеләре: Р.Р.Абызова, Л.Р.Мортазина; фәнни мөхәррире — М.М.Гыйбатдинов. 23 мәкаләне үз эченә алган өч бүлектән («Каюм Насыйриның фәнни-методик эшчәнлеге», «Татарча белем бирү һәм татар телен укыту тарихыннан», «Татарча белем бирү һәм татар телен укытуның актуаль проблемалары») тора.

Беренче бүлек, тулысынча мәгърифәтче галимгә багышланып, аның педагогик, методик, мәгърифәтчелек, тел белеме, шул исәптән лексикография (аерым алганда, сүзлекләр төзү) өлкәләрендәге эшчәнлегенә караган төрле мәсьәләләр М.М.Шәкүрова («Каюм Насыйриның фәнни-методик эшчәнлеге»), Г.Г.*Батыршина* («Каюм Насыйриның татар грамматикасы»), Р.Х.Шәймәрданов («Габделкаюм Насыйриның иҗаты һәм эшчәнлегенең бүгенге көн әһәмияте»), Р.Р.Хөснетдинов («Каюм Насыйри институтының татар теле укыту өлкәсендәге эшчәнлеге»), Р.Р.Абызова («Сәгъди иҗатының Каюм Насыйриның педагогик һәм мәгърифәтчелек карашлары формалашуга йогынтысы»), Л.И.Яруллина («К.Насыйриның «Әнмүзәҗ» хезмәтендә һәм «Ләһҗәи татари» сүзлегендә сузык авазларның язуда бирелеше») мәкаләләрендә яктыртыла.

Чыг.: Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность (Материалы региональной научно-практической конференции, посвященной 190-летию содня рождения Каюма Насыри. Казань, 2015.

И.Х.Хәлиуллин.

Р


РА́ДЛОВ Василий Васильевич (Фридрих Вильгельм) (05.01.1837, Берлин – 12.05.1918, Петроград), шәркыятьче галим, төрки телләр белгече, тел галиме, этнограф, археолог, тәрҗемәче, Петербург Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы (1884).

Берлин университетын тәмамлаганнан соң (1858), Россиядә яши. 1859–1871 елларда — Барнаул шәһәрендә: Алтай, Себер, Казакъстан һәм Урта Азия буйлап экспедицияләрдә йөри; төрки халыкларның телләре, фольклоры, этнографиясе, археологиясе буенча материал туплый. 1871 елдан — Казанда: Казан уку-укыту округының татар, башкорт, кыргыз мәктәпләре инспекторы. 1884 елдан — Санк-Петербургта: Петербург Фәннәр академиясенең Азия (1885–1890), антропология һәм этнография (1894–1918) музейлары директоры. Урта һәм Көнчыгыш Азияне өйрәнү буенча Рус комитетын оештыруны башлап йөрүче һәм рәисе (1903–1918). 1891 елда Петербург Фәннәр академиясенең Монголиягә җибәрелгән Орхон экспедициясе белән җитәкчелек итә, 1898 елда Үзәк Азиягә Турфан экспедициясен оештыра, аның башында танылган археолог һәм этнограф Д.А.Клеменц тора.

В.Радлов — гомуми һәм төрки тел белеменә, төрки телләрнең килеп чыгышына, классификациясенә, тарихи диалектологиясенә, төрки текстология, фольклористика, этнография, археологиягә багышланган фундаменталь хезмәтләр авторы. Ул беренчеләрдән булып борынгы төрки Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләрен укып чыга, борынгы уйгур ядкәрләрен өйрәнә һәм бастырып чыгара башлый. Төрки телләрне чагыштырма-тарихи өйрәнүгә нигез салучыларның берсе; «Төньяк төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы» («Сравнительная грамматика северных тюркских языков», Лейпциг, 1882), «Монголиянең борынгы төрки язулары» («Древнетюркские надписи Монголии», вып. 1–2, СПб., 1894–1895), «Төрки телләр морфологиясен тасвирлауга карата башлангыч фикерләр» («Вводные мысли к описанию морфологии тюркских языков», СПб., 1911) хезмәтләре авторы. Алтай һәм Көнбатыш Себер төрки халыкларына караган төрле лингвистик, фольклор, этнографик материаллар туплап, аларны ун кисәкле «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племён», ч. 1–10, СПб., 1866–1907) басмасы рәвешендә дөньяга чыгара; «Төрки телләр сүзлеге тәҗрибәсе» («Опыт словаря тюркских наречий», 1–4 т., М., 1888–1911) дип аталган күптомлы хезмәтен бастыра.

Казанда яшәгән вакытта (1871–1883) татар галимнәре һәм зыялылары белән аралаша. 1871 елда аның тәкъдиме белән Каюм Насыйри Казанда татар балалары өчен башлангыч *рус-татар мәктәбе* ача һәм шунда укыта башлый. 1872 елдан башлап рус-татар мәктәпләрендә В.В. Радловның «Белек: балалар укыр өчен чыгарылган китап» исемле уку әсбабы кулланыла. Аның максаты — мәктәп укучыларын дөньяви

белемнәр белән таныштыру һәм аларга әхлакый тәрбия бирү. Бу китап сөйләм телендә уку өчен язылган алты тематик бүлектән гыйбарәт. Ул үз эченә географию, астрономия, зоология, тарих һәм башка фәннәр буенча 162 гыйбрәтле хикәя һәм фәнни-популяр очеркны ала. Соңрак алар арасында укыту методикасы мәсьәләләре буенча фикер каршылыклары килеп чыга. 1876 елда мәгърифәтче галим мәктәптән китә һәм берничә ел *Казан татар укытучылар мәктәбендә* укыта, бер үк вакытта фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнә. Бу хәлләр аның замандашы Мөхәммәтхәнәфи *Мозаффар* хатирәсендә түбәндәгечә яктыртыла: «Бәгъзы әфәнделәрдән Каюм Насыйриның Радлов белән килешә алмаенча ышкулда мөгаллимлеген ташлавына сурәт мәсьәләсе сәбәп булган, имеш, дия ишеттем. Ягъни Каюм әфәнде ышкулга патша сурәтен куйдырырга разый булмаенча истигъфа [эштән азат ителү] кылган булган. Бу ялгыш фикернең таралуыннан куркып, бу тугрыда хакыйкатьне язарга мәҗбүр булдым. Татар балалары өчен Шиһаб хәзрәт мәхәлләсендә Ядгяр Шаһи йортында ышкул ачылып, анда Каюм әфәндене мөгаллим кылганнар. Бу йорт Шиһаб хәзрәт мәдрәсәсенә якын булганлыктан, эткәмез үзенең танышы Каюм әфәнде янына кергәли икән. Бер кергәндә Радлов илә дә очрашканнар. Радлов, балаларның кенәгәләрен караганда, берәр җөмләне бозылган тапкан. Төрле баланың кенәгәсен караган, барында да бер төрле бозылганын күргән. Балалардан: «Буны кем бозды?» — дип сораган. Балалар: «Каюм абзый бозды», — дигәннәр. Каюм әфәндегә хитабән (эндәшеп): «Ник болай бу сүзләрне бозды?» — дидекендә Каюм әфәнде: «Бән сәңа «Кырык вәзир»не тәрҗемә кылып укытыйк дидем, анда безем халык шикләнә торган сүз юк. Әмма бу



В.В.Радлов

җөмләләрдән бала аталары нәфрәтләнәләр, ничә бала шул сәбәпле укудан туктады», — дигән. Радлов: «Шушыны укыт, алай бозма!» — дигән. Каюм: «Бән ул сүзләрне укыта алмыйм», — дигән. Радлов: «Укытмасаң, истигъфа кыл», — дигән. Каюм әфәнде: «Хәзердән истигъфа кылдым, бән укыта алмыйм» — дигән һәм шул көннән Каюм әфәнде укытудан туктаган. Сурәт алдыру мәсьәләсенә килсәк, Каюм әфәнденең аңа хилаф (каршы) булмавы беленә. Ул үзе сурәтләр тоткан. Бервакыт әткәмезгә Шиһаб хәзрәт сурәтен күрсәткән. Ләкин инкяр [кире кагу] галәмәте бер дә беленмәгән».

Хезм.: О языке куманов. СПб., 1884; Памятники уйгурского письма. Л., 1928.

Әд.: Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык Казан, 2017; Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1982; Матвеева П.А., Резван Е.А. «Камень на дороге времени» к 175-летию В.В.Радлова // Урало-алтайские исследования. 2012; Очерки по истории русского востоковедения. М., 1953; Помелов В.Б. Просветительско-педагогическая деятельность В.В.Радлова // Педагогика. 2013. № 6; Тюркологический сборник: Памяти В.В.Радлова посвящается. М., 1972.

И.Х.Хәлиуллин.

РАМАЗА́НОВ Шиһабетдин Галим улы (20.12.1887, Саратов губернасының (хәзер Пенза өлкәсенең Лопатин районы) Иске Карлыган авылы – 25.10.1948, Казан), тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1944), Татарстанның халык укытучысы (1927).

Вятка өлкәсенең Сарапул өязе «Буби» мәдрәсәсендә белем алганнан соң, 1907–1924 елларда — Саратов губернасы мәктәпләрендә, 1924–1925 елларда — Саратов, 1930–1931 елларда Әстерхан педагогия техникумнарында укыта. 1934–1947 елларда — Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасында, доцент. Бер үк вакытта, 1942–1948 еллдарда, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1943–1945 елларда Казан университетында эшли.

Хезмәтләре татар грамматикасына, сүз ясалышы, лексикология, терминология, татар әдәби теле тарихы, сөйләм культурасына карый. Руслашкан алфавит төзүдә катнаша. Башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен татар теле дәреслекләре һәм программалары авторы.

Каюм Насыйри турында 1948 елда дөнья күргән «Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары)» басмасында урнаштырылган «Каюм Насыйри татар әдәби теленә нигез салучы» мәкаләсендә Ш.Рамазанов атаклы мәгърифәтчене асылын халыкның гомумсөйләм теле тәшкил иткән әдәби телне нигезләүче галим буларак күрсәтә: «XIX йөзнең соңгы яртысына чаклы татар әдәби теленең теоретик нигезләре, сөйләм һәм язу нормалары, стилистик алымнары билгеләнмичә килде. Татар әдәби телен демократлаштыру, үз туфрагына утыртып, үз җирлегендә тәрбияләп үстерү идеяләрен берәү дә күтәрмәде. Бу мәсьәләләрне Каюм Насыйри күтәреп чыкты. Насыйри татар грамматикасының барлык төр мәсьәләләренә кагыла, аларны билгеле дәрәҗәдә гыйльми нигезләп бирә. Каюм Насыйриның тел өлкәсендәге хезмәтләре татар милли әдәби телнең нигезләрен аныклау, телебезне гыйльми тикшерү юлында беренче тәжрибәләр һәм татар тел белеменең беренчесе булып мәйданга килделәр. Телнең үсешенә, үсеш юнәлешенә аерым кешеләрнең тәэсире барлыгын аңлый, хаксызга кимсетелеп, читләтелеп килгән татар телен әдәби тел һәм фән теле итеп кагыйдәләштерергә, чуалчык урыннарын чишеп, сөйләм һәм язу нормаларын, стилистик алымнарын билгеләргә тырыша. Татар халкының, татар теленең үсеш юнәлешен Насыйри, нигездә, дөрес билгеләде. Ул башлап җибәргән юлны күренекле язучылар дәвам итте», — дип яза.



Ш.Г.Рамазанов

Хезм.: Татар әдәби теленең орфография кагыйдәләре. Казан, 1934 (автордаш); Каюм Насыйри — татар әдәби теленә нигез салучы // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Татар теле буенча очерклар. Казан, 1954.

Әд.: Вәзиева Ж. Талантлы педагог һәм галим // Совет мәктәбе. 1987. № 12; Исламов Ф.Ф. Зур педагог та ул Ш.Рамазанов // Мәгърифәт, әдәбият һәм тарих сукмаклары буенча. Казан, 2002; Казанская лингвистическая школа. Казань, 2008. Кн.1; Якупова Г. Шигап Алимович Рамазанов (к 90-летию со дня рождения) // Советская тюркология. 1978. № 1.

Ф.С.Гыйниятуллина.

РӘХИ́М (Габдрәхимов) Гали Мөхәммәтшакир улы (04.11.1892, Казан – 03.03.1943), әдәбият галиме, язучы, җәмәгать эшлеклесе. Сәүдәгәрләр гаиләсеннән.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән соң Казан сәүдә училищесын (1913), Мәскәү сәүдә институтын (1917) тәмам-

лый, үзлегеннән гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә. 1917 елдан — Казанда: Хәрби-сәяси курсларда (1920–1921) татар әдәбиятын, Шәрекъ академиясендә (1921–1922), Шәрекъ педагогия институтында (1922–1930) татар әдәбияты һәм фольклоры тарихын укта.

1909 елда география буенча «Җир йөзе» исемле беренче фәнни хезмәте басылып чыга. 1913–1915 елларда «Бикчәнтәй угылы» тәхәллүсе белән «Ак юл» журналында балалар өчен хикәя һәм әкиятләрен бастыра. Соңыннан алар башлангыч сыйныфлар өчен дәреслекләргә кертелә, 1923 елда «Кызыл гөлләр» исеме белән аерым китап булып чыга. 1913–1915 елларда «Аң» журналында аның өлкәннәр өчен хикәяләре («Галия», «Исемсез хикәя», «Сабиржан хәзрәт») дөнья күрә. Татар байлары тормышын көлеп тасвирлаган «Дача кайгысы» (1914) һәм «Җанвар» (1919) комедияләрен, революциягә кадәрге татар зыялылары яшәешен күрсәткән «Идел» повестен (1921) иҗат итә. «Татар әдәбияты тарихы» (1–2 т., 1923–1927) китабы авторларының берсе, татар теле һәм әдәбиятына, татар халык авыз иҗатына, тарихына, археографиясенә багышланган мәкаләләр авторы.

1923–1930 елларда Татар халкын өйрәнү фәнни җәмгыяте эшендә, фольклор экспедицияләрендә катнаша. 1925 елда «Вестник Научного общества татароведения» («Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе») басмасында аның рус телендә «Каюм Насыйров (тууына 100 ел тулуга карата)» мәкаләсе басыла. Автор галимне, М.В.Ломоносов белән чагыштырып, «татар әдәби теленең бөек реформаторы һәм мәдәният эшлеклесе», «татар ренессансы дәверенең иң күренекле эшлеклеләреннән берсе», «татарлар арасында беренче фольклорчы», «татар телен фәнни эшкәртүне үз өстенә алган тәүге татар



Г.М.Рәхим

галиме», «татар теленең хәзергәчә бердәнбер булып калган беренче аңлатмалы сүзлеге авторы», «шул заман татарлары арасында Европа фәннәре казанышларын таратуның пионеры», «яңа татар әдәби теленең атасы» дип атый; аның эшчәнлеген өч яссылыкта — галим, фәннәрне популярлаштыручы һәм әдип буларак өйрәнү зарурлыгын ассызыклый; мәгърифәтченең тарихи-археологик материалларының күпчелеге дүрт җыентык рәвешендә И.Ф.*Готвальд* кулъязмалары арасында Казан университеты китапханәсендә саклануын искәртә; аның Казан шәркыятьче галимнәре В.В.*Радлов*, И.Ф.Готвальд, соңрак О.С.Лебедева (*Гөлнар ханым*), Н.Ф.*Катанов* белән аралашуын югары бәяли; шәхесе һәм эшчәнлеге үз вакытында тиешенчә бәяләнмәвенә борчылуын белдерә.

1931–1934, 1938–1940 елларда репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Әсәр.: Халык әдәбиятымызга бер караш: Җырлар. Казан, 1915; Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәм материаллары. Казан, 1926; Авылны өйрәнү: Татар авылларын монография ысулы белән өйрәнү өчен җентекле кулланма-программа. Казан, 1930; Сайланма әсәрләр. Казан, 2004; Каюм Насыров (к 100-летию со дня рождения) // Вестник Научного общества татароведения. 1925. № 1–2.

Әд.: Азизова-Хөснетдинова Г.А. Гали Рәхим — әдәбият тарихчысы. Казан, 2005; Гали Рәхим: Тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык. Казан, 2008; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. Казан, 2005.

И.Х.Хәлиуллин.

РӘХИ́МОВА Резеда Каюм кызы (02.05.1933, Татарстанның Арча районы Урта Пошалым авылы), тел галиме, педагог, филология фәннәре кандидаты (1975).

Арча педагогия училищесын (1952), Казан университетының тарих-филология факультетын (1959) тәмамлый. 1952–1954 елларда Арча районының Иске Төрнәле һәм Урта Пошалым җидееллык мәктәпләрендә укыта. 1959–2007 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының (1996 елдан ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) тел тарихы секторында (соңыннан тел белеме бүлеге) өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли. Шунда ук аспирантурада укый. Татар теленең өч һәм бер томлы аңлатмалы сүзлекләрен (1997, 2005) төзүдә катнаша.

Хезмәтләре татар теленең һөнәрчелек лексикасын өйрәнүгә карый. Бу өлкәдә сүзлекләр төзегәндә Р.Рәхимова Каюм Насыйриның лексикографик һәм башка хезмәтләреннән файдалана; мәсәлән, ювелирлык лексикасына караган сүзлеген төзегәндә, ул галимнең «Санаигы голфания» (1900) китабына таянып эш итә. Андагы гарәп хәрефендәге текстларны рус графикасына күчерә, кулланылган гарәп сүзләренең тәрҗемәләрен эшли, гарәпчә-татарча-русча сүзлеген төзи.

Хезм.: Татар теленең һөнәрчелек лексикасы (туку, өс-баш, аяк киеме тегү, шәл бәйләү, итек басу буенча). Казан, 1983; Татар ювелирлык лексикасы һәм сүзлеге. Казан, 2002; Татарча-русча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге. Казан, 2018; Книга Каюма Насыри: «Санаигъ галвания»: транслитерация, лексика, словарь (к столетию издания книги «Санаигъ галъвания» (1900–2000) и смерти Каюма Насыри (1902–2002) = Каюм Насыйриның «Санаигъ галвания» китабы: транслитерация, лексика, сүзлек («Санаигъ галъвания» китабының басылып чыгуына (1900–2000) һәм Каюм Насыйриның үлүенә (1902–2002) йөз ел тулуга багышлана). Казан, 2002.



Р.К.Рәхимова

Әд.: Кадирова Э.Х. Галимәнең юбилее уңаеннан (Резеда Рәхимовага — 90 яшь) // Фәнни Татарстан. 2023. № 3 (39); Рахимова Резеда Каюмовна // Казанская лингвистическая школа: Кн. первая: Казанская тюркская лингвистическая школа. Казань, 2008.

Р.Ф.Исламов.

РИВАЯ́ТЬ (гарәп теленнән — رواية), фольклор жанры; тарихи шәхесләр, вакыйгалар, төбәкләр турында нәселдән нәселгә күчеп, телдән сөйләнә торган хикәя. Риваятьләр, теге яки бу вакыйгаларда катнашкан кешеләр сөйләве нигезендә барлыкка килеп, сәнгатьчә эшкәртелә. Ышандыру көченә ия. Нигездә, ике төркемгә: тарихи һәм топонимик риваятьләргә бүленә.

Татар риваятьләренең күпчелеге халык тарихы белән бәйле. Тарихи риваятьләренең тематик төркемнәре халык тарихының төп чорларына туры килә. Аларның борынгылары 10–14 йөзләр Болгар иле («Болгар каласының корылуы», «Белемле кеше», «Болгарның харап булуы», «Кырык кыз» һ.б.) тарихына нисбәтле. Аннан соңгыларының күпчелеге, шул исәптән «Утсыз кайный торган казан»; «Туйбикә казаны», «Сөембикә», «Патша хәйләсе», «Явыз Иван ничек Казанга сугыш ачкан» риваятьләре Казан ханлыгы чорына һәм Казан каласына карый.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, өйрәнүгә һәм бастырып

чыгаруга аеруча зур әһәмият бирелә. Ул, татар халык *әкиятләрен*, *бәетләрен*, *җырларын*, *мәкальләрен*, *сынамышларын*, *табышмакларын*, *ырымнарын*, *ышануларын* барлау белән бергә, Казан шәһәре, Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендә яшәүче татар халкы арасында йөргән риваятьләрне җыю һәм өйрәнүне мөһим бурычы саный. Тупланган риваятьләрне, аерым алганда, «Алып әдәмнәр», «Тәварихе Казан», «Бу яңа Казанның гыймәрәт кыйлынганы», «Казан алынганы», «Казанның кадимге планы вә кадимге гыймәрәтләре», «Аксак Каратун әрхәрәй хакында риваятьләр», «Пугачёв хакында әткәй мәрхүм сөйләде»не үзенең тарихи һәм фольклор хезмәтләрендә бастыра. К.Насыйри риваятьләренең кайберләре аның вафатыннан соң дөнья күрә, күпмедер өлеше кулъязма рәвешендә Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә саклана.

К.Насыйри белән бер үк вакытта диярлек төрки риваятьләрне 19 йөз шәркыятьче галиме В.В.*Радлов* та өйрәнә («Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре», 10 бүлек, СПб., 1866–1907).

Әд.: Археология материаллары (Зөя өязе авыллары буенча) // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Болгар, Казан төшми телләрдән: Риваятьләр һәм легендалар // Татар халык иҗаты: Хрестоматия. Казан, 2005; Насыйри Г.Г. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 2024; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987; Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен. 10 частей. СПб., 1866–1907.

Р.В.Шәйдуллин.

РУС-ТАТА́Р МӘКТӘБЕ́, татар балалары өчен башлангыч уку йорты. Әлеге мәктәп системасы Россиядә яшәүче рус булмаган милләт кешеләренә белем бирү чаралары турындагы Халык мәгарифе министрлыгы күрсәтмәләре нигезендә гамәлгә куела, аны 1870 елның 26 мартында император Александр II имзалый. Әлеге күрсәтмәләр империянең рус булмаган халкына карата яңа педагогик идеологияне үстерү өчен кирәк була, аларның нигезендә рус-татар мәктәпләрен һәм мәдрәсәләрдә рус сыйныфлары оештыру, татарларны рус мәдәнияте даирәсендә тәрбияләү мәсьәләләре тора. Башлангыч уку йортлары өчен мөгаллимнәрне *Казан татар укытучылар мәктәбендә* әзерләү карала. Мәктәпләрнең күпчелеге Казан земствосы һәм шәһәр үзидарә органнары тарафыннан, кайберләре Халык мәгарифе министрлыгы хисабына финанслана. Уку срогы — 3 ел, рус теле бердәнбер фән була; арифметика, тел белеме, табигыять фәннәре буенча белешмәләр уку китабында бирелә. Ислам динен чакырылган муллалар укыта, аларга хезмәт хакы земство һәм шәһәр үзидарә органнары тарафыннан түләнә.

Казанда татарлар өчен яңача белем бирү йорты булдыру идеясенең башында татар, башкорт һәм кыргыз мәктәпләре инспекторы В.В.*Радлов* тора. Аның тәкъдиме белән Каюм Насыйри, беренчеләрдән булып, 1871 елдан, 3–5 укучы җыеп, аларны рус теленә өйрәтә башлый. Башта бу эш өйдә белем бирү рәвешендә башкарыла. Үзе билгеләп үткәнчә, Сәгъди Яхин дигән кеше фатирында — аның 4–5 укучысы, соңрак Сая Ибрай номерында 3 шәкерте була. 1872 елның февраль башына кадәр мәктәп өчен тиешле урын таба алмый йөргәннән соң, Казанның Мокрый бистәсендә бер кабак өстендә фатир алып, 10 лап баланы ике ай чамасы укыта. Моннан соң К.Насыйри, үзенең педагогик тәжрибәсеннән чыгып, мәктәпне, нигездә, танышлары-

ның һәм элеккеге укучыларының һәм аларның туганнарының балаларыннан туплый. Шулай итеп, 1872 елның җәендә ул Захарьевский урамындагы 2 нче гильдия сәүдәгәр Шаһиәхмәт Салиховның ике катлы агач йортында бүлмәләр арендалап, рус-татар мәктәбен ачуга ирешә. Анда 20–25 ир балага белем бирә башлый, тиздән аларга тагын 6 малай өстәлә. 1872/73 уку елында К.Насыйри 35 малай өчен уку процессын мәктәп тәртипләрендә оештыра. 1875 елда ул Яңа Татар бистәсендәге рус-татар мәктәбенә күчерелә, аны Ибраһим *Терегулов* алыштыра.

К.Насыйри яңа эш урынында моңа кадәр рус уку йортларында (*Казан өяз руханилар училищесы*, *Казан руханилар семинариясе*, Казан университеты) туплаган уку-укыту тәҗрибәсен киң кулланырга тырыша. Бер үк вакытта укучы балаларга мәктәптән тыш уку өчен үзенең уку әсбабларын, хезмәтләрен һәм кулъязмаларын тәкъдим итә. Аның мондый актив эшчәнлеге укучыларның белемнәрен арттырырга булыша. К.Насыйри рус-татар мәктәбендә дәрес сәгатьләрен үзе билгели. Башлангыч сыйныф укытучысы таныклыгы булмау сәбәпле, мәгърифәтче рус телендә В.В.Радлов рөхсәте белән белем бирә. Ислам нигезләрен укыту өчен, Уфа шәһәрендә Оренбург Мөселман Диния нәзарәтендә сынау узарга кирәк була, ләкин 1870 елларның 1 нче яртысында бу максаттан мәктәпкә указлы мулла чакыру гамәлдә булмый. К.Насыйриның «*Касыймия*» мәдрәсәсен пишкадәм (иң яхшы шәкерт) дәрәҗәсе белән тәмамлавы һәм В.В.Радловның хәерхаһлык күрсәтүе аңа рус-татар мәктәбендә ислам нигезләрен укыту мөмкинлеге бирә.

К.Насыйри мәктәптә үзе төзегән уку-укыту программасы һәм методикасы ярдәмендә белем бирергә омтыла. В.В.Радловның 1873 елдан башлап рус-татар мәктәпләрендә һәм мәдрәсә каршындагы рус сыйныфларында укытыла торган «Арифметика» дәреслегеннән хәбәрдар булу белән, мәгърифәтче шул ук елны «*Хисаплык*» уку әсбабын бастырып чыгара, анда гарәп терминнары урынына татар сүзләрен киң куллана. 1875 елда ул «Татарча-русча лөгать китабы»н (кара: «*Татарско-русский словарь*») нәшер итә. Шулай ук 1871 елдан аның еллык календарьлары чыга башлый. Бу басмалар, В.В.Радлов төзегән дәреслекләр буенча укытыла торган казна мәктәпләрендә рәсми рәвештә кулланыла алмаулары сәбәпле, мәдрәсә шәкертләренә һәм рус-татар мәктәпләре укучыларына мәктәптән тыш уку өчен тәкъдим ителә.

Татар җәмгыятенең кадими өлеше Радлов-Насыйри проектын мөселман дине нигезләрен какшата торган гамәл буларак кабул итә. Мәгърифәтче билгеләп үткәнчә, «бигрәк тә фанатиклар һәм реакционерлар бу кеше бөтен җирдә мөселман динен хур итәргә тели дигән имеш-мимешләр тараталар». Эш шул дәрәҗәгә җитә ки, элеккеге мөгаллимнәр, каршы очраганда, аның белән баш кагып исәнләшми башлыйлар, мөгаллимне Казаннан куып чыгаруны таләп итүчеләр дә табыла; аның укучыларын мәдрәсәдә кыйнап ташлау очраклары да була: кайберләрен рус теле дәресеннән ваз кичәргә мәҗбүр итәләр. Шул ук вакытта рус-татар мәктәпләре инспекторы В.В.Радлов, «һәртөрле байлык вәгъдә итеп», укыту процессына тупас рәвештә тыкшына башлый дигән фаразлар да бар. Испекторның каты басымы турында К.Насыйри «Казанда мөселман балалары өчен беренче рус-татар мәктәбе ачылу» (1876) мәкаләсендә болай дип яза: «Кыска гына вакыт эчендә Германияне монда күчереп утыртып булмас. Бөтен яңа, күнекмәгән нәрсәләр башта халыкка чит тоела. Уңышка

ирешеп булмый, әгәр бу яңалыкны сак, әдәпле итеп үстермәсәң. Халык әкренләп тынычланыр, күнегер, гаделсез шелтә белдермәс. Шундый гадәт килеп чыкты ки, һәр эшне кемдер беренче булып башлый һәм аның өлешенә сүгенүдән башка бернәрсә дә төшми». 1876 елда К.Насыйри рус-татар мәктәбендә укыту эшеннән китә, әмма моның сәбәбе В.В.Радлов белән рус телен укыту методикасы яки дәреслек куллану буенча фикер каршылыклары түгел, ә бәхетсезлек очрагы була: мәгърифәтче эшләгән иске уку йортының черегән идәне җимерелеп, ул тирән чокырга егылып төшә һәм чак кына суга батып үлми кала. Күпмедер вакыттан соң гына аңсыз хәлдә чокырдан чыгарып, аңа беренче медицина ярдәме күрсәтәләр. Бу фаҗигале вакыйгадан соң К.Насыйри, озак дәваланып һәм тирән нерв киеренкелеге кичереп, мәктәпкә кире кайтмый. Мәгърифәтченең шундый карарга килүенә татар җәмәгатьчелегенең аның рус-татар мәктәбендә укыту эшчәнлегенә тискәре йогынтысы да сәбәп була.

Казна уку йортыннан киткәннән соң, К.Насыйри еллар дәвамында тупланган педагогик тәҗрибәсен шәхси мәктәбендә һәм татар шәкертләренә уку әсбаблары әзерләүдә киң куллана. Ул алга таба да, өйдә мөгаллимлек итү эшчәнлеген дәвам итү максатыннан 1876 елның 3 июлендә Оренбург Мөселман Диния нәзарәтендә имтихан биреп, аны уңышлы тапшыра һәм имам-хатип һәм мөдәррис исеменә лаек була. Шул ук елда ачылган Казан татар укытучылар мәктәбендә укыту эшен берничә ел дәвам итә. Әлеге уку йортына ярдәм итәргә теләп, К.Насыйри Петербург басмасының контурлы карталарын, татарча язылган ярымшарлар һәм дөньяның биш кисәге карталарын бушлай тапшыра. Бу уку йортыннан соң да ул мәгърифәт эшчәнлеген бөтенләй үк ташлап бетерми, кайбер татар эшмәкәрләренең һәм зыялыларының балаларын рус теленә өйрәтә.

К.Насыйри үзенең «Казанда мөселман балалары өчен беренче рус-татар мәктәбен ачу» (1876) мәкаләсендә, чиновникларның тәҗрибәсезлегенә һәм кадимчеләрнең каршылыгына карамастан, беренче адымны ясый алдык, дип белдерә. «Барысы да Европа мәктәпләре үрнәгендә төзелгән...», «булачак мөгаллимнәр, һичшиксез, аның тәҗрибәсеннән дөрес нәтиҗәләр ала алачак» дип әйтә. Соңрак әлеге мәктәпләрнең барлыкка килүе *җәдитчелек* таралуга ярдәм итә, сыйныф-дәрес системасының, укырга-язарга өйрәтүдә иҗек-аваз ысулының, чит телне өйрәнгәндә заманча укыту методикасының нәтиҗәлелеген күрсәтә. 1905 елда Казан уку-укыту округында — 31, шул исәптән Казанда 5 рус-татар мәктәбе эшли.

Әд.: Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы // Совет әдәбияты. 1936. № 2; Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Каюм Насыйри мәҗмүгасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Казан, 1922; Гайнуллин М. Каюм Насыри (его научная, литературная и просветительская деятельность). Казань, 1945; Загидуллин И.К. Каюм Насыри — учитель русско-татарской школы Казани (1871–1877 гг.) // Вестник Оренбургского государственного педагогического университета. Электронный научный журнал. 2024. № 4 (52); Закирова Л.Н. Василий Васильевич Радлов: казанский период деятельности. Казань, 2013; Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса, 1861–1917). Казань, 1982; Насыри К. Открытие в Казани первой русско-татарской школы для детей мусульман // Избранные произведения. Казань, 1977; Саматова Ч.Х. Имперская власть и татарская школа во второй половине XIX – начале XX века. Казань, 2013.


Р.В.Шәйдуллин.

С

САБЛУКО́В Гордий Семёнович (1804, Оренбург губернасының Эстәрлетамак өязе Архангельский заводы, башка мәгълүматлар буенча Аскын заводы – 29.01.1880, Казан), төрки, гарәп телләре белгече, ислам дине белгече, миссионер.

Оренбург руханилар семинариясен (1826), Мәскәү руханилар академиясен (1830) тәмамлый. Үзлегеннән фарсы һәм гарәп телләрен өйрәнә. 1830 елдан Саратов руханилар семинариясендә тарих һәм яһүд, грек, татар телләрен, 1849–1862 елдан Казан руханилар академиясендә татар һәм гарәп телләрен укыта. 1849 елдан Православие гыйбадәтләрен татар теленә тәрҗемә итү комиссиясе әгъзасы.

Хезмәтләре Идел буе һәм Алтын Урда тарихына, нумизматика, археология, этнографиягә, шулай ук ислам гыйлеменә карый. Саратовта эшләгән чорда Идел буе халыкларының этнографиясен өйрәнә. Алтын Урданың Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдид һәм Үкәк шәһәрләрендә тарихи-археологик һәм нумизматик тикшеренүләр үткәрә, анда табылган Җучиләр акчалары тупланмасының исемлеген төзи. 1848 елда Ибне Фазланның руслар турындагы хикәятенең Х.Д.Френ бастырган тексты нигезендә тәрҗемәсен басмага әзерли. Татар һәм төрки телләр белеме буенча «Татар грамматикасы», «Рус телендә татар-монгол сүзләрен тарихи-филологик аңлату», «А.Троянскийның 2000 тирәсе китап



Г.С.Саблуков

һәм халык теле сүзләре өстәлгән татарча сүзлеге», «Татар теленең синоним сүзләр җыентыгы» хезмәтләре авторы. Алар Казанда 1856 елның 5 июнендә булган янгын вакытында юкка чыга. Саратовта һәм Казанда Хива ханы һәм тарихчы Әбелгазый Баһадур ханның «Төркиләрнең нәсел шәҗәрәсе» әсәренең төп язмасын өйрәнеп тәрҗемә итә.

Казанда яшәгән чорда ислам гыйлемен өйрәнү белән шөгыльләнә, җирле зыялылар, шул исәптән Каюм Насыйри белән аралаша. Аның тәкъдиме белән мәгърифәтче галим 1855 елда *Казан өяз руханилар училищесына*, соңрак исә *Казан руханилар семинариясенә* татар теле укытучысы буларак эшкә кабул ителә. «Коръән»не (1877) һәм «Коръән тәрҗемәсенә кушымталар»ны (1879) рус теленә тәрҗемә иткәндә һәм хәдисләрне өйрәнгәндә Саблуковның Насыйри киңәшләренә таянуы ихтимал.

Хезм.: Исследование о месте Сарая, столицы Кипчакской Орды // Ученые записки Казанского университета. 1842. Т. 2; История Абуль-Гази // Библиотека восточных историков, издаваемая И.Березиным, профессором Казанского университета. Казань, 1854. Т. 3, ч. 1; Путевые за-

писки двух Хаджиев: 1751 и 1783 года. Казань, 1862; Сведения о Коране, законоположительной книге мохаммеданского вероучения. Казань, 1884; Очерки внутреннего состояния Кипчакского царства // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1896. Т. 13, вып. 3.

Әд.: Библиографик словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период. М., 1989; Валеев Р.М. Из истории Казанского востоковедения середины — второй половины XIX в.: Гордий Семёнович Саблуков — тюрколог и исламовед. Казань, 1993; Крачковский И.Ю. Чернышевский и ориенталист Г.С. Саблуков // Избранные сочинения. М.–Л., 1955. Т. 1.

Р.М.Вәлиев, И.Х.Хәлиуллин.

САДРИ́ЕВ Әхәт Шәйхи улы (02.03.1935, Татарстанның Апас районы Чәтбаш авылы), педагог, ТССРның атказанган мәктәп укытучысы (1990), РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы (1969). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1997).

Тәтеш педагогия училищесын (1955), Казан университетының тарих-филология факультетын (1964) тәмамлый. 1955 елда укытучы булып эшли башлый, армия сафларында хезмәт итә. 1958 елдан — КПССның Апас район комитетында пропагандист, 1959 елдан — Апас районының Кызылтау җидееллык мәктәбендә физкультура һәм рус теле укытучысы, 1960 елдан — Чәтбаш башлангыч мәктәбе мөдире, 1961 елдан — Шонгат урта мәктәбендә укытучы һәм уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары, 1964 елдан — Борнаш урта мәктәбе директоры. 1970 елдан — Апас район мәгариф бүлеге мөдире, 1974 елдан — Борындык урта мәктәбе директоры һәм тарих укытучысы. 1977–1981 елларда — Совет гаскәрләренең Төньяк группасы



Ә.Ш.Садриев

(Польша) 26 нчы мәктәбендә тарих укытучысы, класстан һәм мәктәптән тыш тәрбия эшләрен оештыручы. 1981–1983 елларда — КПСС Апас район комитетының сәяси белем бирү кабинеты консультанты. 1983–1997 елларда — Апас урта мәктәбе директоры һәм тарих укытучысы. 1997–2017 елларда — Яшел Үзән шәһәренең 9 нчы лицеенда тарих укытучысы, музей оештыручы һәм аның җитәкчесе.

Педагогик эшчәнлегенең төп юнәлешләре рухи-әхлакый шәхес формалаштыруга һәм тәрбияләүгә карый. Ә.Садриев мәктәп укучылары белән туган якны өйрәнү һәм музей эшчәнлеге өлкәсендә зур эш башкара. Укучылары белән Апас районының кече елгалары буйлап экологик рейдлар ясый, тарихи әһәмияткә ия булган урыннарга походларга бара. Ул оештырган «Туган як серләре» түгәрәге әгъзалары, ТР, РФ һәм Казакъстанда туган якны өйрәнү һәм экология буенча уздырылган конкурсларда һәм олимпиадаларда актив катнашып, призлы урыннар яулыйлар.

1989 елдан башлап, ТРның «Хәтер китабы» редакциясе белән актив хезмәттәшлек итә. Аның җитәкчелегендә өлкән сыйныф укучылары «Хәтер китабы»ның Апас районы томы өчен сугышта хәбәрсез югалганнарның язмышын ачыклау буенча эш алып баралар. «Хәтер китабы» редколлегиясе әгъзасы буларак, Татарстанда сәяси репрессияләр корбаннары «Хәтер китабы»н һәм «Алар Җиңү белән кайтты» китабын әзерләүгә дә зур өлеш кертә. 1997 елда үзе эшләгән лицейда Советлар

Союзы маршалы Г.К.Жуков музеен оештыра һәм аны 20 ел дәвамында җитәкли. Аңа 1500 дән артык уникаль экспонат туплый. Әлеге музей Бөек Ватан сугышы тарихы музее, ватанпәрвәрлек тәрбиясе үзәгенә әверелә, республика күләмендә киң танылу яулый.

Медальләр белән бүләкләнә.

Әд.: Галиев Ә. Әхәт абый Садриевка 90 яшь. Казан, 2025; Федотов В.А. Патриот. Повесть о школьном учителе истории — настоящем патриоте А.Ш.Садриеве. Казань, 2012.

Р.Р.Сәләхиев.

«САЙЛАНМА́ ӘСӘРЛӘ́Р», Каюм Насыйри әсәрләре җыентыгы. Анда матур әдәбият, рус матбугатында басылган әсәрләр, календарьлар туплана. 1945 елда дөнья күрә. Җаваплы мөхәррире Мөхәммәт *Гайнуллин*. Галимнең сакланып калган кайбер кулъязмалары турында кызыклы белешмә бирелгән сүз башы авторы — *Л.Җәләй*.


Җыентыкта «Әбугалисина кыйссасы» (М.*Гали* аңлатмасы белән), «Кырык вәзир кыйссасы», «Әфсанәи Гөлрөх вә Камәрҗан», «Фәвакиһел җөләса» һәм «Кырык бакча» (Л.Җәләйнең кереш сүзе белән) чәчмә әсәрләре, «Исереклек заманы»: Исереклек хәлләре бәянында гыйбрәт намә» поэмасы, «Җыен» бәете, татар теленә тәрҗемә итеп рус чыганакларында басылган «Салам торхан әкияте», «Җүләр угыл», «Гөлнәзек», «Өч угыл» әкиятләре, «Буш вакыт» китабыннан (Л.Җәләй редакциясендә һәм аның кереш сүзе белән) «Һава», «Һава җисемдер», «Һаваның җәелүе», «Һава насосы», «Һава шары», «Җылылык үлчәве», «Су», «Ягмур (яңгыр)» мәкаләләре урнаштырылган. Шулай ук галимнең сакланып калган кайбер кулъязмалары турында кызыклы белешмә бирелгән.

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945.

Әд.: Фәйзуллин С. Насыйри һәм аның әсәрләре // Совет әдәбияты. 1945. № 3–4; шул ук. Онытылган хәзинә // Кызыл Татарстан. 1945. 20 февраль.

Р.Ф.Исламов.

«САЙЛАНМА́ ӘСӘРЛӘ́Р», Каюм Насыйри әсәрләре җыентыгы. Анда әдәби һәм гыйльми хезмәтләрен-



К.Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1945.



К.Насыйри. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956.

нән үрнәкләр тупланган. 1953 елда дөнья күрә. Мөхәммәт *Гайнуллин* мөхәррирлегендә эшләнә. Текстлар, нигездә, авторның үзе карап бастырган китапларыннан алынып, гамәлдәге орфография һәм пунктуация белән бирелә. Хәзерге укучыга аңлашылмый торган сүзләргә һәр биттә аңлатмалар бар. Теле авыррак булган яки башка телләрдә язылган текстлар исә бүгенге әдәби телгә тәрҗемә ителгән.


Җыентык төзелеше ягыннан 5 өлешкә бүленә: татар һәм рус телләрен өйрәнү («Әнмүзәж», «Ләһҗәи татари», «Русча-татарча лөгать» һ.б.); төрле фәннәрнең әһәмияте турындагы («Гөлзар вә чәмәнзар», «Хисаплык», «Кануны сыйххәт», «Санаигъ голфания» һ.б.); тарих, этнография һәм археологиягә караган хезмәтләре («Пугачау кыйссасы», «Зөя өязе», Гадәтләр, ышанулар һәм гореф-гадәтләр» һ.б.); Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, халык җырлары, халык сүзләре (мәкальләр), әкиятләр); матур әдәбият әсәрләре («Әбүгалисина», «Кырык вәзир», «Гөлрөх вә Камәрҗан» һ.б.). Соңгылары кыскартылып һәм тел ягыннан беркадәр җиңеләйтеп бирелгән. Шулай ук К.Насыйриның тормышы һәм эшчәнлеге турында библиографик белешмәләр урнаштырылган. Җыентыкның икенче басмасы 1956 елда нәшер ителә.

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953; шул ук. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956. 2 нче басмасы.

Әд.: Җәләй Л. Каюм Насыйриның «Сайланма әсәрләре» // Совет әдәбияты. 1953. № 11; Каюм Насыйриның сайланма әсәрләре // Яшь сталинчы. 1953. 27 сентябрь.

Р.Ф.Исламов.

«САЙЛАНМА́ ӘСӘРЛӘ́Р», Каюм Насыйри әсәрләренең ике томлык җыентыгы. Анда әдәби һәм гыйльми хезмәтләреннән үрнәкләр тупланган. 1 нче томы — 1974 елда, 2 нче томы 1975 елда дөнья күрә. Текстлар авторның үзе карап бастырган китапларыннан алынып, нигездә язу стилен саклауны күздә тоткан хәлдә, хәзерге орфография һәм пунктуация белән бирелә. Бүгенге укучыларга аңлашылмый торган сүзләргә



К.Насыйри. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1974, 1975.

һәр биттә аңлатмалар бар. Теле авыррак булган яки башка телләрдә язылган текстлар исә бүгенге әдәби телгә күчерелгән. Төзүчесе, гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче — Мәсгуд *Гайнетдинов*.

Беренче томга телләр өйрәнүгә («Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият», «Әнмүзәж», «Русча-татарча лөгать» һ.б.); тарих, этнография һәм археологиягә караган («Тәварихе Казан», «Казан алынганы», «Алып адәмнәр») хезмәтләр; бәетләр («Рус-француз сугышы бәете», «Чәй бәете» һ.б.); әкиятләр («Салам-Торхан», «Үги кыз», «Гөлнәзек» һ.б.); матур әдәбият әсәрләреннән («Әбүгалисина кыйссасы») өзекләр, халык иҗаты әсәрләре: та-

бышмаклар, сынамышлар һәм әйтемнәр; йорт-җир, кием-салым, ашау-эчү, гореф-гадәтләр турында мәгълүматлар һәм башка хезмәтләреннән өзекләр кертелгән.

Икенче томда К.Насыйриның төрле фәннәргә, шул исәптән археология материалларына, ышанулар һәм гореф-гадәтләр, әхлак һәм тәрбия мәсьәләләренә караган хезмәтләре, әдәби әсәрләре һәм тәрҗемәләре урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Казан, 1974–1975.

Әд.: Каюм Насыйри // Социалистик Татарстан. 1975. 22 июнь; Надиров И. Олы юбилейга лаеклы басма // Социалистик Татарстан. 1975. 30 март.

Р.Ф.Исламов.

«САЙЛАНМА́ ӘСӘРЛӘ́Р», Каюм Насыйри әсәрләренең дүрт томлык җыентыгы. Анда әдәби һәм гыйльми хезмәтләреннән үрнәкләр тупланган. 1 нче һәм 2 нче томнары — 2003 елда, 3 нче томы — 2005 елда, 4 нче томы — 2006 елда дөнья күрә. Беренче, икенче һәм дүртенче томнарын төзүчесе, гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авторы Мәсгуд *Гайнетдинов*; өченче томын төзүчесе, гарәп графикасындагы аерым текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авторы Хуҗиәхмәт *Мәхмутов*.

Беренче томда проза әсәрләре һәм поэма-шигырьләре, 1893 елда Оренбург шәһәренә һәм Сәгыйд бистәсенә (Карагалы авылына) сәфәре турында язмасы, төрле елларда чыккан календарьларында басылган мәкаләләр урнаштырылган. Икенче томда «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» һәм «Җәваһирел хикәят» әсәрләре китерелгән. Өченче томда К.Насыйри җыйган халык ижаты әсәрләре, аның фольклористикага, төбәк тарихына, татар этнографиясенә караган гыйльми хезмәтләре тупланган. Шулай ук «Гөлрох вә Камәрҗан» әсәре, төрле фәннәргә караган хезмәтләреннән өзекләр, галимнең шәхси хатлары бирелгән. Дүртенче томда «Мәҗмәгыль әхбар», «Кабуснамә», «Кырык бакча», «Китаб әт-тәрбия» әсәрләре, мәсәлләр,



К.Насыйри. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2003, 2005, 2006.

тарих буенча материаллар, календарьларыннан төрле темаларга караган мәкаләләр урын алган.


Тарих фәннәре кандидаты Рәшит Кадыйров бу басманы бәяләп шулай дип язды: «Каюм Насыйриның (тулы исеме — Габделкаюм бине Габденнасыйр әш-Шырдани әр-Рәззакый әл-Болгари) бу дүрттомлыкка кергән «Сайланма әсәрләре» — мәшһүр мәгърифәтче язучының әлегә кадәр чыккан басмалары арасында иң тулысы. 1974–1975 елларда нәшер ителгән икетомлыкта бары совет хакимияте цензурасыннан исән-имин үтә алган әсәрләр урын алган иде (хәер, аннан элекке басмалары хакында да шуны ук әйтә алабыз). Милли әдәбиятыбыз тарихында Насыйри исеме уңай яктан телгә алынса да, аның әсәрләренә гомуми

уңай бәяләмә бирелсә дә, әсәрләренең зур күпчелеге укучыга җиткерелмәде, дөресен әйткәндә, бөтенләй кирәксез һәм зарарлы дип саналып киленде. Сәбәбе мәгълүм: дөньяга чыгарылмаган әсәрләре барысы да диярлек дини яки ярымдини. Аларга мөселман Шәркы, мөселман әдәбияты рухы сеңгән, нигезенә совет атеизмына бөтенләй ят принциплар салынган».

Чыг.: Насыйри К. Сайланма әсәрләр: 4 томда. Казан, 2003, 2005–2006.

Р.Ф.Исламов.

«САНА́ИГЫ ГОЛФАНИЯ́», һөнәрчелек буенча кулланма. Анда бер тимер өслеген даими гальваник электр тогы ярдәмендә икенче металлның юка пленкасы белән каплау формалары турында төрле мәгълүматлар китерелә.



К.Насыйри. «Санаигы голфания». Казан, 1900.

Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1900 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә.

К.Насыйри китапның төп эчтәлеген: «Хикмәте гольфания дигәнемез бер фәндер ки, ошбу фәнне белгәннән соң, җиз вә бакыр кебек нәрсәләрне хәтта көлли [барлык] һәрбер нәүгы мәгъданны сәһел тарикча [җиңел юл белән] вә утсыз алтынламак вә көмешләмәк мөмкин буладыр. Әүвәл бу гыйлемне Голфан дигән адәм ихтираг кылмыштыр [уйлап тапкан]. Шул җәһәттән хикмәте голфания тәсмия кылынды [аталды]», — дип аңлата. Китап ахырында терминнарның татарча, гарәпчә, русча сүзлеге бирелгән.

Китапның факсимилесе һәм гамәлдәге татар хәрефләрендәге тексты Р.К.*Рәхимова* тарафыннан рус һәм татар телләрендә бастырылган «Книга Каюма Насыри: «Санаигъ галвания» = Каюм Насыйриның «Санаигъ галвания» дигән хезмәттә дә урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Санаигы голфания. Казан, 1900.

Әд.: Катанов Н. Санаиг гальфание (работы гальванистические). Казань, Типо-литогр. ун-та. 1900. / Н. Катанов // Деятель. 1900. № 12; Рахимова Р.К. Книга Каюма Насыри: «Санаигъ галвания»: транслитерация, лексика, словарь (к столетию издания книги «Санаигъ галвания» (1900–2000) и смерти Каюма Насыри (1902–2002) = Рәхимова Р. К. Каюм Насыйриның «Санаигъ галвания» китабы: транслитерация, лексика, сүзлек («Санаигъ галвания» китабының басылып чыгуына (1900–2000) һәм Каюм Насыйриның үлүенә (1902–2002) йөз ел тулуга багышлана). Казан, 2002.

Р.Ф.Исламов.

САФИ́УЛЛИНА Флёра Садри кызы (24.05.1938, Татарстанның Сарман районы Теләнче-Тамак авылы – 06.12.2011, Казан), тел галиме, филология фәннәре докторы (2001), профессор (1997), ТРның атказанган мәктәп укытучысы (1993), ТРның атка-

занган фән эшлеклесе (2004), Халыкара төркиакадемиянең хакыйкый әгъзасы (1997). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2001).



Ф.С.Сафиуллина

Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлый (1960), шунда ук эшли. 1992–2008 елларда чит ил студентларына татар теле өйрәтү, 2008–2011 елларда гамәли тел белеме һәм тәрҗемәчелек кафедралары мөдире.

Хезмәтләре татар теле лексикографиясе һәм синтаксисына карый. Ул югары уку йортлары һәм урта мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре, татар телен өйрәнүчеләр өчен сүзлекләр, үзөйрәткечләр һәм сөйләшергә өйрәткечләр авторы.

Хезм.: Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. Казан, 1999; Тел гыйлеменә кереш. Казан, 2001; Антонимнар сүзлеге. Казан, 2005; Синтаксис татарской разговорной речи. Казань, 1978; Татарско-русский фразеологический словарь. Казань, 2001; Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Казань, 2007 (автордаш).

Әд.: Фәнгә багышланган гомер. Казан, 2008; Казанская лингвистическая школа. Казань, 2008.

Ф.С.Гыйниятуллина.

СӘГЫЙД (СӘЕТ) БИСТӘСЕ́, татарлар нигез салган торак пункт. 1744 елда Оренбург шәһәреннән 18 чакрым төньяктарак Каргалы елгасы (Сакмар елгасының уң кушылдыгы) буенда барлыкка килә. Аның җирлегенә Казан губернасыннан салымнардан һәм хәрби бурычтан азат ителгән 200 ләп татар гаиләсе килеп утыра. Әлеге бистә Оренбург крае наместнигы И.И.Неплюевның Урта Азия һәм Шәрекъ илләре белән сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салу һәм үстерү максатындагы үтенече буенча нигезләнә. Башта торак пунктны нигезләүче Сәгыйд Хәялин исеме белән Сәгыйд бистәсе дип йөртелә. Хәзер Оренбург өлкәсенең Сакмар районы Татар Каргалысы авылы.

Бистәдә яшәүче татар сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре Россиянең Урта Азия ханлыклары һәм Казакъстан белән икътисади элемтәләрдә актив катнашалар. Бистә тиз арада үсеп китә.



Татар Каргалысы авылының «Куш манара» мәчете. 1749 ел.

18 йөз ахырында анда яшәүчеләрнең саны 1,5 мең кеше тәшкил итә, 1835 елда — 5 мең тирәсе, 1897 елда 13 меңнән артык кеше (башлыча, татарлар) яши. Бистә кешеләре тарафыннан Оренбург губернасында 30 дан артык авылга нигез салына. 18 йөздә – 19 йөз башында Россия һәм Урта Азия арасында эре транзит сәүдәсе үзәге була. Төп халкы һөнәрчелек (22 төрле сәнәгать оешмасы, 20 ләп су тегермәне), сәүдә, игенчелек белән шөгыльләнә. Оренбург төбәгендәге татар мәдәнияте үзәге: 20 йөз башында анда мәдрәсәләре һәм мәктәпләре булган 10 нан артык мәчет

исәпләнә. Бистәдә күренекле татар шагыйрьләре Ә.Каргалый, Г.Утыз Имәни, сәүдәгәр Хөсәеновлар — «Хөсәения» мәдрәсәсен нигезләүчеләр һәм башкалар яши.

1893 елның маенда, өч юлдашы белән бергә, Каюм Насыйри Самара, Оренбург шәһәрләрендә, Сәгыйд бистәсендә, бистәнең зиратында була. Хаҗи ахун аларны кунакка ала. Әлеге сәяхәттә күргәннәрен 1894 елгы календаренда басылган «Сәфәр» юлъязмасында бәян итеп, кыскача бистәнең, аны нигезләүченең тарихы, тормышлары һәм эшчәнлекләре аның белән бәйле күренекле шәхесләр: шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Әбелмәних Каргалый, шагыйрь, дин эшлеклесе Һибәтулла Салихов, дин эшлеклесе һәм галиме Ишнияз әл-Харәзми әл-Үргәнчи, Казан шәһәрендәге 5 нче таш мәчетнең имамы һәм мөдәррисе мелла Сәгыйть *әш-Шырдани* белән таныштыра.

Чыг.: Насыйри Г. Сәфәр // Календарь 1894 елга. Казан, 1893; шул ук. Сәфәр // Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017.

Әд.: Оренбург сәүдәгәрләре. Оренбург, 1996; Фәхретдинов Р. Сәид шәһәре. Казан, 1897; Искандаров А., Искандаров Р. Сеитов посад: Очерки по истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. Казань, 2005.

И.Х.Хәлиуллин.

СӘГЪДИ́ (Сәгъдиев) Габдрахман Гайнан улы (26.03.1889, Уфа губернасының Златоуст өязе (хәзер Башкортстанның Салават районы) Таймый авылы – 06.11.1956, Үзбәкстан ССР, Сәмәрканд шәһәре), әдәбият галиме, педагог, филология фәннәре докторы (1949).

Троицкида «Рәсүлия» мәдрәсәсендә (1902–1906), Истанбул университетында (1908–1911) белем ала. 1917



Г.Г.Сәгъди

елга кадәр укыта. 1918–1921 елларда Бөгелмәдә татар-башкорт педагогия курсларында укытучы һәм мөдир вазифасын башкара. 1921–1925 елларда Үзбәкстан ирләр һәм хатын-кызлар мәгариф институтларында, Ташкент шәһәренең Урта Азия университетында эшли. 1925–1930 елларда Татарстан коммунистик университетында һәм Казан Көнчыгыш педагогия институтында (1929 елдан — профессор) укыта. 1930 елдан кабат Урта Азиядә: 1930–1932, 1937–1941, 1952–1956 елларда Үзбәкстан педагогия академиясендә (Сәмәрканд), 1932–1937 елларда Ташкент педагогия институтында, 1941–1952 елларда Урта Азия университетында белем бирә.

Эшчәнлеге тел һәм әдәбият укыту мәсьәләләренә, дәреслекләр, методик кулланмалар төзүгә карый. Галим шулай ук әдәбият теориясе, татар теле морфологиясе һәм синтаксисы, педагогика һәм татар әдәбиятын укыту методикасы тарихы, үзбәк, төрекмән һәм башкорт әдәбиятлары тарихы, шәрекъ педагогикасы буенча дәреслекләр авторы.

Г.Сәгъди татар, үзбәк, казакъ, төрекмән телләрендә бай әдәби мирас калдыра. Әдәбият тарихын синхрон һәм диахрон аспектларда өйрәнә. «Татар әдәбияты тарихы» (1926) хезмәтендә әдәби процессны тел, иҗтимагый фикер, мәгариф, дин, фән үсеше контекстында карый. «Символизм турында» китабында «ысул-агым-мәктәп» системасында әдәбият күренешләрен танып белү һәм бәяләү методологиясенең зарурилыгын теоретик яктан дәлилли.

Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри турында мәкаләләр язучы буларак та билгеле галим. Ул аны татар халкының бөек патриот язучы-журналисты һәм зур галим-филологы, саф татар әдәби теленең һәм әдәбиятының нигез коручысы дип атый. «Каюм Насыйриның хезмәтләре татар халкы өчен, беренче башлап чәчелгән алдынгы культура орлыклары буларак, зур яңалык бирде. XIX гасырның икенче ярымы татар халкының культура, әдәби үсешендә көнчыгыштан көнбатышка таба нык борылыш ясаган бер дәвер иде. Менә шул зур тарихи борылышның төп фикери буынын, тамырын Каюм Насыйриның практик һәм теоретик хезмәтләре, аның иҗаты, аның әсәрләре тәшкил итте. Бу татар халкы эчендә Каюм Насыйрида әүвәлге культура Хадимнәрендә булмаган һәм күренмәгән беренче зур фикер һәм культура яңалыгы иде һәм культура үсешендә революцион-демократик хәрәкәтнең нигез ташын салучыларның берсе иде. Каюм Насыйри татар халкы өчен иң кирәкле булган зур һәм уңышлы эшне, һәрнәрсәдән әүвәл, бөек рус халкы белән чыннан дуслашу һәм шул көчле халыктан зур гыйльми һәм культура ярдәме алу аркасында эшли алды. Ул рус культурасы һәм гыйлем дөньясының татар халкы өчен хәзерләнгән иң туклыклы беренче җимеше булып җитеште. Каюм Насыйри әсәрләре мәйданга килгәнче, XIX гасырның икенче ярымында, төп татар әдәби теле татар халкының үзендә, аның сөйләшү телендә, җырларында, мәкаль һәм табышмакларында, бәет һәм әкиятләрендә, кыскасы, авыз әдәбиятында, фольклорында гына иде; язма әдәбиятта чын татар теле юк иде. Язудагы чын татар әсәре — әдәби телнең нигезен Каюм Насыйри салды. Каюм Насыйри тарафыннан төп нигез салынган әнә шул җанлы әдәби тел совет матбугаты, татар совет язучылары һәм шагыйрьләре тарафыннан бу көнге күтәрелеш баскычына үсте һәм инде ул күп камилләште», — дип язды автор үзенең мәкаләсендә.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Хезм.: Әдәбият дәресләре. Ташкент, 1925; Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсеше. Казан, 1926; Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан, 1930; Татар халкының үсешендә Каюм Насыйриның роле // Совет әдәбияты. 1944. № 10.

Әд.: Габдрахман Сәгъди: Фәнни-биографик җыентык. Казан, 2008; Гыйззәтуллин Н. Габдрахман Сәгъди // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. Казан, 2005; Исламов Ф. Мәгърифәт, әдәбият һәм тарих сукмаклары буйлап. Казан, 2002.

Ф.С.Гыйниятуллина.

СИКСӘНЕНЧЕ́ МӘКТӘП, Каюм Насыйри исемендәге аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 80 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе. Казан шәһәре Вахитов районында урнашкан.

Мәктәпнең тарихы 1922 елдан Зыя Вакыйф җитәкчелегендә беренче баскыч берләштерелгән мәктәптән башлана. Ул Мулланур Вахитов исемендәге мәктәп шәһәрчеге дип йөртелә. Аңа Тукай, Нариманов урамнарын-



Сиксәненче мәктәп.



дагы берничә бина, шул исәптән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасы да керә. 1935 елда мәктәп дүрт катлы бинага күченә һәм шунда 33 сыйныф (1185 укучы) тәүге уку елын башлап җибәрә. Беренче чыгарылыш 1937 елда була. 1939 елга кадәр — 1 нче мәктәп; 1939 елның мартыннан — 80 нче мәктәп дип йөртелә, 1939 елда драматург һәм прозаик Шәриф Камал исеме бирелә. 1950–1960 елларда — Казан педагогия институтының база мәктәбе.



1964 елга кадәр укыту татар телендә алып барыла. Аннан соң татар-рус мәктәбе дип атала башлый, укытуда рус теленә күчү башлана. 1978 елда янкорма төзелә. 1992 елда кабат татар сыйныфлары ачыла. Укучыларның милли составы: татарлар — 53 %, руслар — 38 %, башка милләт вәкилләре — 9 % (2021).

2021 елда мәктәп директоры Р.М.*Мансуров* башлангычында уку йортына Каюм Насыйри исеме бирелә. 2022 елда проект төзелеп, мәгърифәтченең ике шәкерте арасында утырып торган образы гәүдәләндерелгән «Каюм Насыйри: мәдрәсәдән — дөньяви мәктәпкә» скульптур композициясе эшләнеп, мәктәп эчендәге мәйданчыкта урнаштырыла (сынчы Х.Х.Миннегалиев), 2023 елда мәктәпнең «Каюм Насыйри варислары» дип аталган гимны языла (Х.Мостафин сүзләре, И.Зарипов көе). Гимнның тексты: Халкым өчен белем учагына / Ут кабызган Каюм Насыйри. / Балкып тора, сүнми яктылыгы, / Узса да ул ничә гасырны. Каюм Насыйри, Каюм Насыйри — / Йөзек кашы безнең милләтнең. / Еллар үтә, гасырлар да үтә, / Арта гына бара кыйммәте.

Мәктәптә А.С.Ключарев исемендәге 7 нче музыка мәктәбе филиалы, «Мирас» бию ансамбле эшли. Ул Каюм Насыйри институты бүлекчәсе, Вахитов районының Балалар иҗаты үзәге белән хезмәттәшлек итә. Төрле чаралар, шул исәптән «Ак калфак» татар хатын-кызларының төбәк иҗтимагый оешмасы, Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә «Татар малае — 2022» шәһәр конкурсының 1 нче туры (2022), «Насыйри укулары — Насыровские чтения» халыкара фәнни-гамәли конференциясе (2022 елдан), шулай ук милли көрәш буенча традицион «Каюм батыр» ярышлары уздырыла.

И.Х.Хәлиуллин.

СМИРНО́В Василий Дмитриевич (28.07.1846, Әстерхан губернасының Әстерхан өязе Бирючья Коса авылы – 25.05.1922, Петроград), шәркыятьче галим, китап гыйлеме белгече, цензор,

төрек-татар теле һәм әдәбияты докторы (1887).

Петербург университетының Шәрекъ бүлеген тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1884–1922 елларда төрек-татар теле һәм әдәбияты профессоры. Бер үк вакытта, 1880–1905 елларда, Петербург цензура комитетында татар китабы цензоры.



В.Д.Смирнов

Цензор сыйфатында ул үзен кадимче буларак таныта, күп кенә фәнни-популяр һәм матур әдәбиятны, рус классикасы тәрҗемәләрен бастыруны тыя. Полиция департаментына татар әдәбиятындагы күп кенә әсәрләрнең «зарарлы» юнәлеше турында яза, татар телендә вакытлы матбугат оештыруга каршы була. 1885–1893 елларда «Рус археология җәмгыятенең шәрекъ бүлеге язмалары»нда Россиядәге мөселман әдәбиятына күзәтүләр бастыра (китап белеме буенча әһәмиятле чыганак булып тора). Аерым алганда, басманың 1888 елда дөнья күргән кушма 3–4 томында урын алган мәкаләсендә, Каюм Насыйри эшчәнлегенең әһәмиятен ассызыклап: «Яңарак кына Россиянең мөселман матбугаты турыдан-туры күчерү — Константинопольдә басылган китаплардан укыту белән генә чикләнәләр иде. Хәзер... татарлар үзләренең туган телләрендә мөстәкыйль әсәрләр иҗат итә башладылар. Алар арасында Каюм Насыйровның «Фәвакиһел җөләса»сын һәм ел саен чыга килгән календарьларын билгеләп үтү зарур», — дип яза.

Хезмәтләре госманлылар империясе һәм Кырым ханлыгы, Төркия һәм төрек әдәбияты тарихына карый.

Хезм.: Кучибей Гёмурджинский и другие османские писатели о причинах упадка Турции. СПб., 1873; Крымское ханство под верховенством Османской империи до начала XVIII века. СПб., 1887; Мусульманские печатные издания в России // Записки Восточного отделения Русского археологического общества. СПб., 1888. Т. III, IV.

И.Х.Хәлиуллин.

«СОВЕ́Т ӘДӘБИЯТЫ́», айлык әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал. 1922 елның маеннан татар телендә Казанда нәшер ителә. ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы органы буларак чыга башлый. 1923 елның мартыннан — ТАССР Мәгариф халык комиссариаты, 1925 елдан — РКБ(б)ның Татарстан өлкә комитеты агитация һәм пропаганда бүлеге, 1928 елдан — Татар мәдәният йорты органы. 1930 елга кадәр «Безнең юл» исеме белән чыга; 1930 елда бүленә (1930–1932 елларда 2 журнал чыга: «Атака» — Татар пролетар язучылары ассоциациясе органы; «Яңалиф» — ТАССР Мәгариф халык комиссариаты һәм Татар совет язучылары җәмгыяте органы). 1933 елда «Атака» һәм «Яңалиф» урынына «Совет әдәбияты» журналы нәшер ителә башлый. 1934 елдан — ТАССР Язучылар берлеге органы. Әлеге журнал 1939 елга кадәр латин графикасында, аннары кириллица язуында басыла.

Беренче көннәрендә үк «Совет әдәбияты» журналы социалистик реализм алымы үсешенә зур игътибар юнәлтә. 1948 елдан әдәби һәм иҗтимагый-сәяси басмага әверелә. Анда әдәби әсәрләр өстенлек итә. Басмада мәгърифәтче галим Каюм Насыйриның тормыш юлын, фәнни-педагогик эшчәнлеген яктыртуга зур урын бирелә, әлеге юнәлештә төрле елларда

Әхмәт *Хөсәенов* (1940, №7: «Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр»), Гали *Халит* (1940, №8: «Әбүгалисина кыйссасы турында»), Мөхәммәт *Гайнуллин* (1944, №1, №2–3: «Атаклы галим һәм язучы Каюм Насыйри»; 1945, №2: «Каюм Насыйри документларда»; 1950, №2: «Бөек мәгърифәтче һәм патриот»), Габдрахман *Сәгъди* (1944, №10: «Татар халкының үсешендә Каюм Насыйриның роле»), Җамал *Вәзиева* (1945, №2: «Каюм Насыйри — тәрбияче»), Латыйф *Җәләй* (1945, №2: «Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри»), Миргазиз *Укмасый* (1945, №2: «Каюм абзый Насыйри (Истәлек)», Вәли *Хангилдин* (1945, №2: «Каюм Насыйри грамматикаларында татар теле синтаксисы нигезләре»), Мөхәммәт *Гали* (1950, №2: «Каюм Насыйриның басылмаган кулъязмасы»), Хисам *Мөхәммәтов* (1955, №2: «К.Насыйриның мәгърифәтчелек карашлары (Тууына 130 ел тулу уңае белән)») мәкаләләре басыла.

1965 елдан журнал «Казан утлары» исеме белән нәшер ителә. Элекечә үк Каюм Насыйри турындагы материалларга җитди игътибар юнәлтелә; аерым алганда, журналда галимнең вафатына 70 ел тулуга багышланган Хуҗиәхмәт *Мәхмүтов* язмасы (1972, №3: «Алтын бөртекләр (К.Насыйри сүзлекләрендә фольклор әсәрләре)») басылып чыга. 1975 елгы 2 нче сан Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулуга багышланып, анда Яхъя *Абдуллин* («Каюм Насыйри иҗатында мораль-этика мәсьәләләре»; 1985, №4: «Күренекле мәгърифәтчебез»), Солтанморад *Акбиев* («Каюм Насыйри һәм Әбусуфьян Акаев»), Әбрар *Кәримуллин* («Каюм Насыйриның «Таң йолдызы» проекты»), Рушания *Хөснетдинова* (1998, №4: «Андыйлар табигатьтә сирәк оч-рый») һәм башкаларның мәкаләләре дөнья күрә.

Әд.: Мәрдиева М. Рухи тормыш көзгесе // Тонус. 1996. №1; Сафина Р. Журналыбызны кемнәр җитәкләгән? // Казан утлары. 1992. №5; Фәйзуллин Р. Бу гасырда да балкыр! // Казан утлары. 2002. №5.

И.Х.Хәлиуллин.

«СОВЕ́Т МӘКТӘБЕ́», иҗтимагый-педагогик, фәнни-әдәби айлык журнал. 1913 елдан чыгып килгән «Мәктәп» журналының дәвамчысы. Эчке Россия мөселман эшләре комиссариатының Гыйльми һәйәте органы буларак, «Мәгариф» исеме белән 1918 елның 7 ноябреннән Казанда татар телендә нәшер ителә башлый. Оештыручылары: беренче мөхәррире — Г.*Ибраһимов* һәм Казан губерна мәгариф халык комиссары Ш.*Әхмәдиев*. 1936 елда исеме «Башлангыч мәктәп» дип үзгәртелә. 1938–1941, 1949–1990 елларда журнал «Совет мәктәбе» буларак чыга.

Басмада мәгърифәтче галим Каюм Насыйриның тормыш юлын, фәнни-педагогик эшчәнлеген яктыртуга зур урын бирелә, әлеге юнәлештә Гасыйм *Лотфиның* (1950, № 1: «Каюм Насыйри — педагог (К.Насыйриның тууына 125 ел тулу уңае белән)»), Мөхәммәт *Гайнуллинның* (1952, №4: «Мәгърифәтче, педагог Каюм Насыйриның үлүенә 50 ел»), Якуб *Ханбиковның* (1962, №9: «Каюм Насыйри хезмәт тәрбиясе турында»; 1975, №2: «К.Насыйриның фәнни педагогик эшчәнлеге»), Абдулла *Әсәдуллинның* (1965, №2: «Каюм Насыйри»), Валентин *Беркутовның* (1969, №5: «Насыйриның математик кулъязмалары»), Яхъя *Абдуллинның* (1971, № 1: «Каюм Насыйри мирасында шәхес тәрбияләү мәсьәләләре»), Байназар *Әлминовның* (1975, №3: «Каюм Насыйриның портреты ничек ту-

ды»), Н.Хәйруллинаның (1982, №11: «К.Насыйри — география дәреслекләре авторы») һәм башкаларның мәкаләләре дөнья күрә.

1990 елдан кабат «Мәгариф» исеме белән чыга. Каюм Насыйри турында яңа материаллар, шул исәптән Шамил *Җәләлиевнең* (2001, №6: «Каюм Насыйри иҗатында татар халык тәрбия тәжрибәсе»), Рәсимә *Шәмсетдиноваың* (2006, №3: «Каюм Насыйри хезмәтләрендә химик атамалар») һ.б.ның язмалары басыла.

Журнал үзенең эшчәнлеге дәверендә иң билгеле татар вакытлы матбугаты басмаларының берсе булып кала. Ул татар милли мәктәбе үсешенә һәм педагогик кадрларның квалификациясен күтәрүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Әд.: Шәрифуллин Ф. Узган юлга күз салсак... // Мәгариф. 2003. №3; Надиев Н. О татарском педагогическом журнале «Магариф» // Просвещение и жизнь. 1929. № 1.

И.Х.Хәлиуллин.

СЫНАМЫ́Ш, фольклор жанры төре. Дәвамлы күзәтүләргә, практик тәжрибәгә яисә төрле ышануларга нигезләнгән алдан әйтү, фаразлау, киңәшне үз эченә ала. Эчтәлеге ягыннан мәҗүсилек гореф-гадәтләренә, йолаларга барып тоташа.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, өйрәнүгә һәм бастырып чыгаруга аеруча зур әһәмият бирелә. Ул татар халык *әкиятләрен, бәетләрен, җырларын, мәкальләрен, табышмакларын, риваятьләрен, ырымнарын, ышануларын* барлау белән бергә Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендәге татар халкы арасында йөргән сынамышларны җыю һәм өйрәнүгә дә зур игътибар биргән.

Татар халкы сынамышларында күк җисемнәрен, табигать күренешләрен, үсемлекләрне, хайваннарны һ.б.ны күзәтүгә нигезләнгән һава торышын һәм булачак уңышны фаразлау, авыл хуҗалыгы эшләре буенча киңәшләр китерелгән. К.Насыйри өйрәнгән сынамышлардан мисаллар: «Яз көнне кар явып, өйдә калган терлек кычкырса, кар тиз эреп, терлек кырга тиз чыгар»; «Шомырт агачы башыннан башлап чәчәк атса, иртә чәчкән бодайлар уңа»; «Шомырт агачы түбәннән башлап чәчәк атса, бары соң чәчкән бодай гына уңа»; «Әгәр кыш көне Иделдә боз өем-өем булып торса, җәен ашлык уңа». Шулай ук кара: *Ышанулар*.

Әд.: Насыйри Г.Г. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 2024; Сынамышлар // Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казан, 1987; Насыров К. Поверья и обряды Казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки Императорского Русского Географического Общества. По отделению Этнографии. СПб., 1880. Т. 6.

Ф.Р.Бәдретдинова.

Т

ТАБЫШМА́К, фольклорның афористик жанры. Табышмакта берәр әйбернең яисә күренешнең киная белән сурәтләп әйтелгән мәгънәсен тиз табу сорала. Бик борынгы *фольклор* жанрларыннан булуы ихтимал. Аның барлыкка килүе хайваннар кешеләр телен аңлыйлар дигән ышануга нигезләнгән, теге яки бу сүзләрне әйтүне тыю (табу) белән бәйле. Табулаштырылган сүзләр табышмакта башка сүзләр белән алыштырылган.

Татар табышмакларын чагыштыруга нигезләнгән, метонимиягә нигезләнгән, аваз ияртемнәренә нигезләнгән һәм арифметик төрләргә бүлеп карыйлар. Аларда кояш һәм башка күк җисемнәре, явым-төшемнәр, үсемлекләр һәм хайваннар образлары; шулай ук татар мифологиясе персонажлары — Алып, Аждаһа, Дию һ.б. бик популяр. Вакытлар үтү белән, жанрның функцияләре һәм куллану даирәсе үзгәрә — табышмаклар күңел ачу һәм тәрбия өлкәсенә, балалар фольклорына күчә.

Фольклористиканы фән буларак нигезләгән Каюм Насыйри, Казан губернасы Зөя өязенең Айдар, Бакырчы, Бәчек, Борнаш, Борындык, Кормаш, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Мулла Иле, Норлат, Югары Шырдан (Кече Шырдан), Цивильск өязенең Шигали авылларында җирле халыктан сораштырып халык авыз иҗаты әсәрләрен җыйнап туплау барышында табышмакларны да терки, аларны «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)» (28 табышмак), «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» (27 табышмак), «Ләһҗәи татари» (150 гә якын мәкаль, әйтем һәм табышмак, күп кенә җырлар һәм такмаклар) хезмәтләренә кертә, календарьларында бастыра. Шулай ук кара: *Әкият*, *Җыр*, *Мәкаль*.

Чыг.: Насыров А.К. Образцы народной литературы казанских татар (загадки, пословицы, песни) // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1896. Т. XIII, вып. 5.

Әд.: Мәхмүтов Х.Ш. Кечкенә дә төш кенә: Табышмакларның жанр үзенчәлекләре. Казан, 1980; Татар халык иҗаты: Табышмаклар. Казан, 1977; Татар халык табышмаклары. Казан, 1970.

И.Х.Хәлиуллин.

«ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ́», кара: *Вакытлы матбугат.*

ТАРИ́Х (борынгы грек теленнән historia — сүзгә сүз тәрҗемәдә табигатьнең һәм кешелекнең үткәне турында хикәя), гуманитар фән. Кешелек җәмгыятенең үткәндәге үсеш юлын һәм хәзерге яшәешен тулы төгәллеге һәм күптөрлелеге белән өйрәнә. Тарак мәгънәдә тарих — вакыйгаларның эзлеклелеген, тасвирланган фактларның дөреслеген билгеләү һәм вакыйгаларның сәбәпләре турында нәтиҗәләр ясау өчен үткәннәр турында төр-

ле чыганакларны өйрәнүче фән. Үткән заманнар турында мәгълүмати белемнәр алу өчен галимнәр матди, язма, сурәт (рәсем, фото һ.б.), халык авыз иҗатына һәм гореф-гадәтләргә караган тарихи чыганакларны өйрәнәләр. Бу гыйлемнең төп максаты — хәзерге һәм киләчәк тормышка аңлы караш булдыру һәм үткәннәргә нәтиҗә ясау.

Тарих — күптармаклы фән, ул тарихи белемнең күп кенә мөстәкыйль тармакларыннан — гражданлык тарихы, сәяси, икътисади, социаль, хәрби тарих, дәүләт һәм хокук, дин тарихыннан һ.б. гыйбарәт. Тарих фәннәренә, ярдәмчел фәнни тармаклар буларак, этнография (халыкларның көнкүрешен һәм мәдәниятен өйрәнә); археология (кешелекнең әүвәлге яшәешен артефактлар: хезмәт кораллары, йорт кирәк-яраклары, бизәнү әйберләре һ.б. ярдәмендә өйрәнә); эпиграфика (каты материаллардагы — таш, керамика, металл һ.б. — язуларның эчтәлеген һәм формаларын өйрәнә); генеология (индивидларның килеп чыгышын һәм алар арасындагы туганлык мөнәсәбәтләрен билгели, шулай ук аерым ыруларның килеп чыгышларын һәм аларның чорның социаль-икътисади һәм иҗтимагый тормышындагы ролен өйрәнә) керә.

Казан төбәгендә тарихның фән буларак үсеше Идел буе Болгар дәүләте барлыкка килгән вакыттан башлана. Алтын Урда һәм аның таркалуыннан соң 15 йөздә барлыкка килгән татар ханлыклары чорында алга таба үсеш ала. Бу чорлар турында төрки телле төрле чыганаклар сакланып калган, аз санлы булсалар да, алар татар халкы тарихи үсешенең аерым якларын күзалларга мөмкинлек бирә.

Рус дәүләте чорында татарлар арасында тарихи эзләнүләр күбесенчә *шәҗәрәләр* төзү рәвешендә бара. Гаилә, ыруг, кайбер очракларда авыл халкы шәҗәрәләре дә төзелә, шулар нигезендә кулъязма китаплар барлыкка килә башлый. Дөньяви мәгълүматлардан тыш, әлеге кулъязмаларда гарәп һәм фарсы китапларыннан күчереп язылган дини-фәлсәфи материаллар зур урын били. Кулъязма китапларның шулай ук кулъязма күчермәләре эшләнеп, алар татар авылларының укымышлы кешеләре арасында тарала, татар мөгалимнәре тарафыннан шәкертләрне укыту өчен дә файдаланыла. Гомуми дини-милли идеологияне саклап калу шартлары тудырып, татарлар арасында яңа гыйлемле затлар үстерүдә ярдәм итә. Шул укумышлылар арасында Каюм Насыйриның бабалары һәм әтисе Габденнасыйр Хөсәенов та була. Алар үзләре яшәгән чорга хас булган ысулларда Коръән һәм башка дини китапларны күчерү белән шөгыльләнәләр. Шулай ук тел белеменә, медицинага һәм башка фәннәргә караган гарәп, фарсы телләрендәге әдәбият татар халкы аларны үзенең көндәлек тормышында куллана алырлык итеп яраклаштырып языла, аларга комментарийлар төзелә.

Үзенең элгәреге буынннары, туганнарыннан аермалы буларак, К.Насыйри тарихи тикшеренүләргә күпьяклап якын килә, аның тарихи эшчәнлегендә *археология*, *этнография*, *эпиграфика*, генеология мәсьәләләре аеруча зур урын алып тора. Атасы ягыннан нәсел шәҗәрәсен төзүдән башланган кызыксынулары аны алга таба Казан губернасының Зөя һәм Цивильск өязләре авылларын, соңрак Казан шәһәрен тарихи-археологик, этнографик һәм эпиграфик яктан өйрәнүгә алып килә. Югары Шырдан (хәзер *Кече Шырдан*) авылына җәйге сәфәрләре вакытында ул Идел буе Болгары дәүләте, Казан ханлыгы чорындагы авыл-

лыклар һәм шәһәрлекләр урнашкан урыннарны, авыл зиратларындагы кабер ташларын өйрәнә, авыл укымышлыларыннан татарлар тарихына караган төрле тарихи риваятьләр, этнографик материаллар җыя. Ул «Казан каласы», «Хан мәчете», «Кабан күле», «Әммә тавы», «Касыйм Шәех», «Ишбулат мулла», «Аксак Каратун» (Лука Конашевич), «Пугачев яулары», «Зөя кальгасы» һәм башка тарихи урыннар һәм затлар турында берничә дистә тарихи-археологик ядкәр таба. (Шулай ук кара: *Риваять*). Әлеге эзләнү эшләрен үткәрүдә аның *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* әгъзасы булуы, Казан университеты профессорлары Н.Ф.*Катанов*, В.В.*Радлов*, И.Ф.*Готвальд*, Н.А.Фирсов, Г.С.*Саблуков* белән якын танышлыгы һәм башка тарихчы галимнәр белән аралашып яшәве зур роль уйный. Җыелган тарихи-археологик материалларның бер өлешен ул, эшкәртеп, үзенең календарьларына кертә, икенче өлеше вафатыннан соң нәшер ителгән «*Каюм Насыйриның мәҗмугасы*» (1922), «*Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга*» (1926) исемле җыентыкларында дөнья күрә.

Мәгърифәтченең календарьларында Казан губернасы, аның өязләре һәм шунда яшәүче укымышлы кешеләр турында тарихи материаллар бар. Аның «Казан шәһәре» (1870), «Казан губернасындагы мөселманнар өязе-өязе белән» (1877) мәкаләләрендә Казан шәһәрендә һәм Казан губернасында яшәүче халыклар хакында тарихи-демографик мәгълүматлар, шул исәптән ир-атлар һәм хатын-кызлар исәбе, никахлар, туучылар һәм үлүчеләр саны, авыллар (тулай саннары китерелеп), шәһәр һәм өязләрнең атамалары бирелә. «Некролог һәм кабер ташлары» (1876), «Кыска тәварих һәм кабер ташлары» (1877) язмаларында татар зыялы затлары — дин белгечләре, мәгърифәтчеләр һәм язучылар Габденнасыйр Курсави, Габдерәхим Утыз Имәни, Мөхәммәд Чәләби, Сәгыйть бине Әхмәт *әш-Шырдани*, Ибраһим бине Хуҗаш, Таһир бине Сөбханкол һәм башкаларның тәржемәи хәлләре һәм төрле юнәлештәге эшчәнлекләре яктыртыла.

Шулай ук К.Насыйри Россия тарихы буенча татар телендә беренчеләрдән булып «*Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь*» (1890) китабын язып бастыра. Анда конспект рәвешендә рус бөек князьләренең һәм патшаларының эшчәнлеге тасвирлана. Моннан тыш, үзенең еллык календарьларында да ул Россия тарихына багышланган бик күп мәкалә («Русиянең башланганы» (1870), «Падишаһымыз хәзрәтләренең нәсел-ыругы бәянында» (1870); «Русиядәге губерналар бәянында» (1870); «Русиядә ничә төрле халык» (1871); «Русиядәге ярминкәләр» (1872) һ.б.) бастыра. Мәсәлән, «Русия тәварихыннан берничә сәхифә», «Мәскәү мәмләкәте» мәкаләләрендә (1872) Новгород, Галич-Волынь, Чернигов, Смоленск, Суздаль һәм башка князьлекләр, монгол яулары һәм Мәскәү бөек кенәзе Иван Калитадан башлап император Александар III гә кадәр идарә иткән патшалар турында тарихи язмалар китерелә.

К.Насыйри татар гыйлем ияләре арасында беренчеләрдән булып татар халкының этнографиясе мәсьәләләренә, шул исәптән йорт-җир, кием-салым, йолаларына (балага исем кушу, бишек туе, гакыйка корбаннары, сөннәткә утырту, кыз яучылау, туй мәҗлесе, бүләк багу, кияү кертү, как-төш мәҗлесе, килен төшерү һ.б.), *сынамышлар*, *ышанулар*, *ырымнар*, юрауларга зур игътибар бирә. Милли аш-су әзерләүгә махсус «Иршад әл-әтбиха» («Пешекчегә аш-су әзерләү турында юллама»,1894) китабын багышлый. Р.Ф.*Шәфигуллина* билгеләп үткәнчә, «китапның төп өлешен-

дә татар милли ризыклары һәм әчемлекләрен әзерләү рецептлары белән бергә башка шәркый-мөселман милләтләренә хас булган тәгамнәр дә бирелә». Галим мәгърифәтче үзенең календарьларында ризык әзерләү рецептлары урнаштыра. Мәсәлән, «Йорт өчен йимеш киптермәк вә йимешләрдән мөрәбба хәзерләмәк» мәкаләсендә алма һәм миләш җимешләрен киптерү һәм алардан компот ясау ысуллары өйрәтелә.

Казан галиме Р.Г.*Фәхретдинов* «Каюм Насыйриның Казан татарларының тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә керткән өлеше» исемле мәкаләсендә мәгърифәтченең «башлыча халык авыз иҗаты әсәрләрен, тарих-эпиграфика мәгълүматларын, этнография, археология материалларын теркәү һәм аларны аңлату-бәянлау юлы белән Казан татарларының борынгы тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә өлеш кертүенең тикшеренүчеләрнең кырда алып барган фәнни эзләнүләрне җирле халыктан сораштырулар белән бергә үреп алып барган алдагы буыны — археологлар һәм эпиграфика белгечләренең эшчәнлеге өчен үрнәк булуын, аның Казан ханлыгы чоры эпиграфика истәлекләрен беренче булып өйрәнүче икәнлеген, Казан тарихы буенча материаллар җыюын һәм бастырып дөньяга чыгаруының зур әһәмиятен» бәян итә.

Чыг.: Насыйров Г. Казан шәһәре // Казан календаре 1872 елга. Казан, 1871; шул ук. Русия тәварихыннан берничә сәхифә // Казан календаре 1872 елга. Казан, 1871; шул ук. Мәскәү мәмләкәте // Казан календаре 1872 елга. Казан, 1871; шул ук. Казан губернасындагы мөселманнар өязе-өязе белән // Календарь 1877 елга. Казан, 1876; шул ук. Некролог һәм кабер ташлары // Календарь 1877 елга. Казан, 1876; шул ук. Казан шәһәре хакында риваять // Календарь 1881 елга. Казан, 1880; шул ук. Казанның кадимге ихатасы хакында риваятьләр // Календарь 1882 елга. Казан, 1881; шул ук. Әммә тавы хакында риваятьләр // Календарь 1882 елга. Казан, 1881; шул ук. Хан мәсҗеде хакында риваятьләр // Календарь 1882 елга. Казан, 1881; шул ук. Кабан күле хакында риваятьләр // Календарь 1882 елга. Казан, 1881; шул ук. Йорт өчен йимеш киптермәк вә йимешләрдән мөрәбба хәзерләмәк // Календарь 1888 елга. Казан, 1887; шул ук. Иршад әл-әтбиха. Казан, 2015. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 2024; шул ук. Поверья и обряды казанских татар // Записки императорского Русского географического общества. 1880.

Әд.: Гимади Х. О трудах К.Насыри в области собирания историко-археологических материалов // Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвященных 120-летию со дня рождения). Казань, 1948; Уразманова Р.К. Каюм Насыри как этнограф // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Фахретдинов Р.Г. Вклад Каюма Насыри в исследование истории и археологии казанских татар // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Р.В.Шәйдуллин.

ТАТА́Р МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕГЕ́, 18–19 йөзләрдә татар җәмгыятендә иҗтимагый-сәяси агым. Аның нигезендә җәмгыять үсешендә аның хәлиткеч роле турында идеалистик күзаллау, җәмгыяттәге кимчелекләрне халыкның наданлыгы, үз табигатьләрен белмәве белән аңлату ята. Рус мәгърифәтчелегендәге кебек үк, татар мәгърифәтчелегенә дә патриархаль нигезләрне, дини һәм әхлакый катып калганлыкны, схоластика, хорафатларны тәнкыйтьләү; табигатькә һәм җәмгыятькә рациональ мөнәсәбәт хас.

Татар мәгърифәтчелеге 18 йөзнең 2 нче яртысында, социаль-икътисади

үзгәрешләр һәм татар халкы арасында башланган чуалышлар (Морад мулла, Батырша һ.б. хәрәкәтләр) татар җәмгыятендәге патриархаль нигезләргә реформа кирәклеген, татар халкының белемен һәм мәдәниятен күтәрү зарурлыгын аңлауга китергәннән соң барлыкка килә. Татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәтенә Батырша (Габдулла Галиев), Габденнасыйр Курсави, Габдерәхим Утыз Имәни, Хөсәен Фәезханов, Шиһабетдин *Мәрҗани*, Каюм Насыйри һ.б. башлангыч бирәләр. Татар җәмгыятен үзгәртеп коруга омтылган идеологлар дөньяга караш принципларының төп юнәлешләрен эшләүдә фикер каршылыгына киләләр. Мәгърифәтчеләрнең кайберләре (Морад мулла, Габдерәхим Утыз Имәни, Баһаветдин Вәисов) татар җәмгыятен реформалау концепциясен социаль утопия рәвешендә куя, икенчеләре (Габденнасыйр Курсави) шул чорда яшәп килгән иске карашларга һәм соңгы мөселман традицияләренә (тәкълид) иярүчеләргә иҗтиһад принципларын каршы куеп (Коръән һәм Сөннә нигезендә дин һәм иҗтимагый тормыш мәсьәләләрендә үз фикереңне әйтү хокукы), мөселман дине кагыйдәләренә реформа ясарга тәкъдим итә, өченчеләр (Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Баруди, Р.*Фәхретдинов*) фәнгә һәм алдынгы мәдәниятка татар җәмгыятенең киң даирәсен тарту зарур дип саный. Татар мәгърифәтчелеге идеологиясе тарафдарлары, нигездә, туып килүче буржуазия вәкилләре түгел, ә мөселман руханилары мохитеннән үсеп чыккан татар зыялылары. Татар җәмгыятенең иҗтимагый-сәяси нигезләренә радикаль мәгърифәт һәм мәдәният реформалары өчен көрәш татар мәгърифәтчеләренең төп шигаре була. 19 йөзнең 2 нче яртысында, патриархаль нигезләр таркалган һәм татар буржуазиясе формалашкан чорда, Татар мәгърифәтчелеге идеологиясе иҗтимагый-сәяси төсмер ала һәм *җәдитчелекнең* бер юнәлешенә әверелә.

Татар мәгърифәтчелеге үсешендә Каюм Насыйриның карашлары аерым урын били. Аның эшчәнлеге үзенчәлекләренең мөһим юнәлешләренең берсе үз халкын — русларның һәм Европаның казанышлары, русларны татар мәдәнияте казанышлары белән таныштыруга омтылыштан гыйбарәт, моңа ирешү нәтиҗәлерәк булсын өчен татарлар тарафыннан рус телен үзләштерүне алга сөрә. Ул яшәгән чор дини идеология тулаем хакимлек иткән вакыт булудан бигрәк татар халкы тормышына алдынгы карашлар үтеп кергән, татар һәм рус халыклары арасында аңлашу тирәнәя барган заман буларак сыйфатлана, әлеге ике халык мәдәниятләренең үзара якынаюында галимнең гамәли эшчәнлеге һәм фәнни хезмәтләре тарихи әһәмияткә ия, алар иреккә, тигез хокуклылыкка, милли изүгә каршы һәм халыклар арасындагы дуслык мөнәсәбәтләренә юнәлтелә. Аның төрле фән тармакларына (әдәбият, тарих, археология, этнография, халык медицинасы, этика һәм эстетика, география, ботаника, зоология, математика, физика, педагогика һ.б.) караган 40 лап хезмәт язып бастыруы, тарих һәм этнография өлкәләрендә татар халкының этник үзбилгеләнүе һәм үзаң, килеп чыгышы һәм теленең үзенчәлеге, мөстәкыйльлеге мәсьәләләрен кыю рәвештә көн тәртибенә куюы, табигать күренешләрен материалистик асылда аңлатуы мәгърифәтченең мирасын өйрәнүчеләр тарафыннан югары бәяләнә; галимнең традицияләре фән, мәдәният һәм сәнгатьнең киләчәк буын вәкилләре тарафыннан дәвам иттерелә, аларның кайберләре (Мөхетдин *Кор-*

бангалиев һ.б.) аны үзләренең остазы дип атый, аның эшчәнлегенең игелекле йогынтысын таныйлар (Габдулла *Тукай*, Фатих *Әмирхан*, Габдерәшит Ибраһимов, Мәҗит Гафури һ.б.).

Әд.: Кәримуллин Ә. Каюм Насыйриның «Таң йолдызы» проекты // Казан утлары. 1975. №2; шул ук. Каюм Насыйри календарьлары // Әйдә халыкка хезмәткә: Күренекле татар публицистлары. Казан, 1985; Мәгърифәтче галимгә багышлап // Казан утлары. 2000. №4; Мөхәррәмов М.К. Күренекле татар галиме һәм демократы // Татарстан коммунисты. 1975. №5 (автордаш); Адыгамов Р.К. Габдрахим Утыз-Имяни. Казань, 2005; Валидов Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.–П., 1923; Закиев М.З. К.Насыри и формирование современного татарского национального языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Идиятуллина Г. Абу-н-Наср Курсави. Казань, 2005; Михайлова С.М. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья (1800–1861). Казань, 1972; Мухарямов М., Абдуллин Я. Выдающийся татарский мыслитель-демократ // Коммунист Татарии. 1975. №1; Мухарямов М.К. Каюм Насыри и его эпоха // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Фасеев К.Ф. Из истории татарской передовой общественной мысли. Казань, 1955; Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX веков (эволюция, основные направления и представители). Казань, 1998. Кн. 1.

И.Х.Хәлиуллин.

«ТАТА́РСКО-РУ́ССКИЙ СЛОВА́РЬ» («Татарча-русча лөгать китабы»), практик белешмәлек, кулланма. Каюм Насыйри тарафыннан татарларга рус теле, русларга татар теле өйрәтү максатында төзелә. 1859 елда язылa башлый һәм китап белән сәүдә итүче Фәтхулла Амашов аны 1878 елда Казан университет басмаханәсендә нәшер итә.

Сүзлекнең татарча төп текстында 3 меңнән артык сүз тупланган. Татар сүзләре гарәп әлифбасы нигезендә төзелгән. Гарәп һәм фарсы сүзләренең бары тик киң кулланылышта булганнары гына алынган. Диалекталь һәм архаик сүзләр дә урын алган. Тәрҗемә сүзгә-сүз ясалган. Алар күбесенчә бер яки ике сүз белән бирелеп, кайберләрендә генә берничә сүз белән бирелгән.

Бу сүзлек турында Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфетдин әл-Кустрамави «Шура» журналында (1912) бастырган «Габделкаюм ән-Насыйри хәзрәтләре тәрҗемәи хәленә гаид» мәкаләсендә: «Габделкаюм әфәнденең әһәмиятле әсәрләре җөмләсеннән «Татарча-русча лөгать китабы» вар. Бу китапта татар сүзләре әлифба тәртибенчә улып вә асыл тотылып, рус лөгатендәге мокабилләре язылган вә рәгъбәтле [үрнәкле] сурәттә табыг [нәшер] ителгән», — дип яза.

Чыг.: Насыйри К. Татарско-русский словарь. Казань, 1878.

Әд.: Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфеттдин әл-Кустрамави. Габделкаюм ән-Насыйри хәзрәтләре тәрҗемәи хәленә гаид // Шура. 1912. № 8; Хангильдин В. Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Р.Ф.Исламов.

ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ ДӘҮЛӘ́Т АРХИВЫ́, 1919 елның 6 февралендә Казан губерна архивы буларак оештырыла. 1921 елдан — Татарстан Үзәк архивы. Исеме берничә мәртәбә үзгәртелә, 2016 елдан — хәзерге исемдә.

Дәүләт архивында 8 меңнән артык фонд, 1709–2024 елларга караган 2 млн нан артык саклау берәмлеге бар (аерым документлар 11–17 йөзләргә карый). Архив документларында төбәкнең сәнәгать, фән, мәдәният һәм мәгариф үсеше, банклар эше, матбугат, иҗтимагый хәрәкәтләр һәм оешмалар, коры җир һәм су транспорты коммуникацияләрен төзү тарихын, күренекле шәхесләрнең (шул исәптән татар әдәбияты классиклары Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Галиәскәр Камал, мәгърифәтчеләр Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри) тормышын һәм эшчәнлеген яктыртканчыганаклар, социаль катлау учреждениеләре документлары, мөселман һәм христиан метрика кенәгәләре, тәүбә язмалары һәм ревизия тасвирламаларында генеалогик мәгълүматлар бар; профессорлар П.В.Знаменский, М.А.Машанов, Н.И.Ильминский, М.К.Казимбәк, Н.Ф.Катановның шәхси фондларында — 11, 15–19 йөзләргә караган рус, француз, немец, грек, латин, гарәп, фарсы, төрек, монгол, тибет һәм башка телләрдәге кулъязмалар тупланган.

Каюм Насыйриның шәхси фонды (970 нче фонд) 1860–1916 елларга караган 22 саклау берәмлеген, шул исәптән татар, гарәп, төрек телләрендәге «Утыз вәгазь», «Календарь хакында кайбер төшенчәләр», «Вәзир турында әкиятләр», рус-татар сүзлеге, география, арифметика, грамматика, табигыять гыйлеме һәм башкаларның кулъязмаларын, басылып чыккан «Кырык бакча», «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият», «Кырык вәзир кыйссасы» әсәрләрен һәм башка хезмәтләрен үз эченә ала.

Әд.: Горохова Л. История традиционной культуры народов Поволжья в документах Национального архива Республики Татарстан // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2006. № 1; Национальный архив Республики Татарстан: Путеводитель. Казань, 1999. Шарафутдинов Д. 85 лет государственной архивной службе Республики Татарстан // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2003. №1/2.

И.Х.Хәлиуллин.

ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ́ МУЗЕ́Е, фәнни-тикшеренү һәм мәдәни-агарту учреждениесе; ТР музейлары өчен музей белеме һәм методика үзәге. Баш музейны һәм филиалларны эченә ала. 1894 елда А.Ф.Лихачёвның шәхси коллекциясе һәм 1890 елда Казанда үткәрелгән фән-сәнәгать күргәзмәсе экспонатлары нигезендә Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музее буларак нигезләнә. 1918 елдан Казан губерна музее. Исеме берничә мәртәбә үзгәртелә, 2001 елдан — хәзерге исемдә.

Музей фондларында 910 меңнән артык саклау берәмлеге бар. Археология фонды музей җыелмасының өчтән бер өлешен тәшкил итә. Нумизматика коллекцияләре 120 меңнән артык саклау берәмлегеннән тора. Этнография коллекциясе (25 меңнән артык саклау берәмлеге) Урта Идел буе халыклары: татарлар, руслар, марилар, удмуртлар, мордвалар, чуашлар, башкортларның көнкүреш предметларын, киемнәрен, бизәнү әйберләрен эченә ала. Әйберләр фондында — 12,2 мең, кораллар фондында төрле чорларга караган 915 саклау берәмлеге исәпләнә.

Фондта шулай ук 16–20 йөзләр язма чыганакларының 130 меңнән артык саклау берәмлеге (алар арасында — Сәхибгәрәй хан ярлыгы (1523)), 17 йөз кулъязма төргәкләре, фән һәм мәдәният эшлеклеләренең архивлары, коллекцияләре һәм автографлары исәпләнә. Сирәк китаплар фондының төп өлешен (22 мең саклау берәмлеге) рус,

татар һәм Көнбатыш Европа телләрендә язылган 17–20 йөзләр Россия, җирле һәм чит ил басмалары тәшкил итә. Уникаль кулъязма һәм иске басма китаплар бүлекчәсе 15–20 йөзләргә караган 233 басма, 90 нан артык кулъязма китапны үз эченә ала.

Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте чыганаклары фондының нигезендә — татар мәдәнияте эшлеклеләренең шәхси әйберләре һәм китаплары. Алар арасында Шиһабетдин *Мәрҗани*, Каюм Насыйри, Габдулла *Тукай*, Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), Ризаэтдин *Фәхретдин*, Гаяз *Исхакый*, Хөсәен Ямашев, Муса Җәлил һ.б.ның мемориаль әйберләре коллекцияләре, татар халкының рухи мәдәниятеннән материаллар бар.

Фондның К.Насыйрига нисбәтле өлеше күбесенчә 1945 елда аның тууына багышлап уздырылган зур шәһәр күргәзмәсеннән, юбилей тантаналарыннан соң күргәзмәнең музейның әдәбият бүлегенә тапшырылган материалларыннан тарих экспозициясендә оештырылган К.Насыйри почмагыннан башлангыч ала. Галимгә багышланган бүлекчәнең шул чордан 1975 елга кадәрге утыз еллык тарихы Д.Б.*Баһаветдинованың* 1976 елда дөнья күргән «Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри» («Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри») җыентыгында урнаштырылган «ТАССР Дәүләт музеенда Каюм Насыйри фонды» мәкаләсендә яктыртыла. Анда бәян ителгәнчә, күргәзмәдән кергән материаллар арасында К.Насыйриның Б.М.*Әлминов* тарафыннан ясалган портрет сурәтләре, С.С.*Ахун* эшләгән скульптура бюсты, әдәби әсәрләренә иллюстрацияләр, галимнең 1880 елларда Казанда *Перов И.С. ташбасмаханәсендә* басылган, 13 буында 250 ләп исем күрсәтелгән куе ябалдашлы имән рәвешендәге, аеруча мөһим сыйфатта бәяләнгән *шәҗәрәсе* була. 1950 елларда музейга К.Насыйриның, Казан тарихына багышланып, шәһәрнең күп кенә архитектура истәлекләре, урамнары тасвирланган 11 битлек кулъязмасы, Буа өязенең икътисады һәм географиясе сурәтләнгән кулъязмасы саклауга алына.

Алга таба К.Насыйри фонды мәгърифәтченең музейга шәхси архивлар составында, шулай ук аерым кешеләр тарафыннан тапшырылган китаплары хисабына тулылана. Музейда сакланучы уникаль экспонатлар арасында — К.Насыйриның 1965 елда Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсеннән алдырылган күк җисемнәре дөньясы глобусы (кара: *География*). Риваятьләрнең берсендә аны галимнең үзе үк эшләве искәртелә. 1972 елда музейга Әгерҗе районы Балтач авылыннан Мөхәммәт Саттаров галимнең «Гөлзар вә чәмәнзар», Казан шәһәрендә яшәгән Риза Шәрәф «Гыйльме зирагать» китапларын тапшыралар. Алдагы дистәләрчә елларда да К.Насыйри фонды яңа өстәлгән экспонатлар, шул исәптән аның үзе исән чакта дөнья күргән әсәрләренең басмалары белән тулылана бара.

Музейда күренекле шәхесләргә багышланган чаралар уздыруга зур игътибар бирелә. 2016 елның декабрендә анда К.Насыйриның, дүрт ел дәвамында язып һәм 1886 елда төгәлләп, үзе тарафыннан «иҗтиһадымның иң олысы» дип бәяләнгән, яңарак кына тәүге тапкыр басылган «Мифтах әл-Коръән» хезмәте тәкъдим ителә. Тәкъдим итү чарасында хезмәт кулъязмасының төп нөсхәсе, галимнең хатлары, шулай ук Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең *кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге* фондында сак-

ланган кулъязмалары һәм басма хезмәтләре күрсәтелә.

Әд.: Багаутдинова Д.Б. Фонд Каюма Насыри в Государственном музее ТАССР // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Дьяконов В.М. Жизнь и музей. М., 1963; Муханов Г.С. История Государственного музея Республики Татарстан в зеркале XX века. Казань, 1997; Назипова Г.Р.Казанский городской музей: Очерки истории 1895–1917 годов. Казань, 2000; Наследие веков: Из собраний Государственного музея Республики Татарстан: Альбом. Казань, 2000.

И.Х.Хәлиуллин.

ТАҺИРИ́ Һади (?–?), шагыйрь, Каюм Насыйри турында истәлек язучы. Екатеринбург шәһәрендә яшәп, «Шура» журналында шигырьләр, хикәяләр һәм мәкаләләр язып бастыра.

«Шура» журналында (1912) аның К.Насыйри турындагы истәлеге дөнья күрә. Автор анда К.Насыйриның Югары Шырдан (*Кече Шырдан*) авылында тууы, аның туганнары турында сүз алып бара; мәгърифәтченең басма әсәрләре, кулъязмалары һәм тарихи кәгазьләрен Габделмән бине Габделхәй кулында күрүе хакында бәян итә. Сәүдәгәр Габделхәй китаплар җыю белән кызыксына, Кече Шырдан авылындагы беренче мәхәллә мәчете аның тарафыннан төзеттерелә. Һ.Таһири К.Насыйрины: «Габделкаюм әфәнде безнең күрше авылымыздан вә кадәремездән улса да табигате салкын улып, кеше илә катышуны сөймәгәннән вә, икенче тарафтан, үзем дә Курсави, Мәржани, Насыйри мисалында гыйлем вә мәгърифәт әһелләрене сөйми торган 19 нчы гасыр шәкертләре җөмләсеннән улдыгымнан ихтилят [аралашу, танышу] кыла алмадым...», — дип искә ала.

Хезм.: Таһири Һ. Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләр // Шура. 1912. №23.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ТАШКИЧҮ́ ГОМУМИ́ БЕЛЕ́М БИРҮ́ МӘКТӘБЕ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү муниципаль уку йорты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2009). Татарстанның Арча муниципаль районы Ташкичү авылында урнашкан. 1929 елда дүртьеллык мәктәп буларак ачыла, 2011 елдан — төп гомуми белем бирү мәктәбе. 2024 елда мәктәптә 53 укучы белем ала, 14 педагог эшли.

Эшчәнлегендә татар халкының гореф-гадәтләрен, телен саклау һәм үстерүгә, аның гомуммәдәни кыйммәтләрен киләчәк буынга тапшыруга, яшьләрне халык мәдәнияте чыганакларына җәлеп итүгә, аларда рухи һәм әхлакый сыйфатлар булдыруга, мәдәни традицияләргә карата кызыксыну уятуга юнәлеш тота.

«Каюм Насыйриның 185 еллыгы уңаеннан мәктәпкүләм укулар» (2010), «Каюм Насыйри — тәрбияче» тәрбия сәгатьләре (2011), ата-аналар җыелышында Каюм Насыйриның «Китап әт-тәрбия» хезмәтендәге тәгъбир-нәсыйхәтләре белән таныштыру (2012), Каюм Насыйриның тууына 190 ел (2015) һәм 195 ел (2020) тулу уңаеннан әдәби кичәләр, укучылар арасында «Каюм Насыйри — бөек шәхес» презентацияләр бәйгесе (2023) уздырыла, мәктәп Каюм Насыйри исемендәге XXI халыкара яшьләр фәнни-гамәли конференциясендә (2023) һәм башка чараларда катнаша.


К.Насыйри исемендәге бүләк милли мәгарифне үстерүдә һәм, Татарстан халыклары милли мәдәниятенең традицияләренә таянып, белем һәм тәр-

бия бирүдә яхшы нәтиҗәләргә ирешкәне өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

«ТӘРБИЯ́ КИТАБЫ́», балаларны тәрбияләү максатында дидактик характерда язылган китап. Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1891 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә. Кереш өлештәге аталышы буенча аны «Китаб әт-тәрбия» дип йөртәләр.

Тәрбия мәсьәләләрен К.Насыйри үзе нәшер иткән календарьларында да күтәреп чыга. Мәсәлән, 1887 елда басылган календарьдагы «Гайнетдин»


تربیه کتابی

عبدالنیوم ملا عبدالناصر اوغلی‌نڭ تصنیفی در

К.Насыйри. «Тәрбия китабы». Казан, 1891.

мәкаләсендә балаларны укыту-тәрбия итү эшләрендә булган кайбер җитешсезлекләрне тәнкыйтьли, эш барышында нинди фәнни чыганаклардан файдаланырга кирәклеген күрсәтә. «Тәрбия» төшенчәсенең мәгънәсен Каюм Насыйри: «Китаб әт-тәрбия», ягъни балаларны тәрбия кылмак бәянында бер китаптыр. Әммә «тәрбия кылмак» вә «тәрбия итмәк» дигән сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки ашатып-эчертеп үстермәк вә баланың холкын-фигылен ислах кылмак [үзгәртү] вә төзәтмәк, вә хайваныяттан чыкарып инсаният [кешелек] дәрәҗәсенә китермәк, вә тәгълим бирмәк, вә үгрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп-әркян [әдәплек терәге] бирмәк мәгънәсендәдер», — дип аңлата.

Китап йөз дә ундүрт тәрбия-киңәштән гыйбарәт. Алар, нигездә, Мөхәммәд, Муса пәйгамбәрләрнең, борынгы грек, гарәп, фарсы дөньяларында киң билгеле булган шәхесләрнең тормышында вакыйгаларга таянып бәян ителә. Мәсәлән, әдәп турындагы уналтынчы тәрбиядә: «Локман хәкимнән сорадылар: «Син әдәпне кемнән үгрәндең?» — диделәр. Локман әйтте: «Әдәпсезләрнең әдәпсезлеген күреп, үземә килешмәгән кебек булды да, һаман андаен фигыльләрдән саклана килдем, әдәпле булдым», — диде. Әй угыл, гакыллы балага атлам саен гыйбрәтләр бар, вәгазьләр бар, мәгърифәт хасыйл итә күр», — диелә.

Китапның икенче, тулырак басмасы Казан университеты басмаханәсендә 1898 елда дөнья күрә. Ул «Китаб әт-тәрбия» исеме белән 1992, 1994, 2021, 2024 елларда татар һәм рус телләрендә басылып чыга. Текстның бик кыска өлеше Каюм Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1953, 1956), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең икенче томына (1975), тулысынча дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең (2003–2006) дүртенче томына (2006) урнаштырылган.

Чыг.: Насыйри К. Тәрбия китабы. Казан, 1891; шул ук. Китаб әт-тәрбия = Насыри К. Книга о воспитании. Казан, 1992.

Әд.: Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Катанов Н. «Тәрбия китабы» (книга о воспитании). Казань, 1898. Тип. ун-та. // Деятель. 1898. № 6–7.

Р.Ф.Исламов.

ТЕЛ БЕЛЕМЕ́, лингвистика, кешеләрнең аралашу чарасы булган табигый тел һәм дөньядагы барлык телләр турындагы фән. Ул тел күренешләрен, аның төзелеш закончалыкларын һәм функцияләрен өйрәнә. Өйрәнү аспектларыннан чыгып, шартлы рәвештә эчке һәм тышкы лингвистиканы аерып карыйлар. Эчке лингвистикага гомуми тел белеме (гомумтел категорияләрен өйрәнә), чагыштырма һәм чагыштырма-тарихи тел белеме (төрле телләр арасындагы генетик һәм типологик мөнәсәбәтләрне өйрәнә), тел системасын төрле юнәлештә өйрәнүче тел белеме тармаклары — фонетика, фонология, грамматика (морфология, сүз ясалышы, синтаксис), морфонология, лексикология, фразеология керә. Тел системасының үсеш этапларын — тел тарихы (тарихи фонетика, фонология һ.б.) һәм этимология, ялгызлык исемнәрне — ономастика, шул исәптән топонимика һәм антропонимика өйрәнә. Тышкы лингвистика (паралингвистика, этнолингвистика, психолингвистика, социолингвистика һ.б.) җәмгыятьтә сөйләүче кеше функцияләре белән бәйле тел аспектларын тикшерә. Аңа шулай ук диалектология һәм лингвистик география дә керә. Татар тел белеменең махсус тармагын интерлингвистика тәшкил итә. Ул халыкара аралашуның төрле аспектлары, халыкара ясалма телләр белән шөгыльләнә.

Татар тел белеме 10–11 йөзләрдә гарәп филологиясе, шул исәптән Мәхмүд Кашгариның гәрәп телендә язылган «Төрки шивәләр җыелмасы» («Диване лөгать әт-түрк», 1072–1074) сүзлеге йогынтысында нигез салынган тюркологиянең бер өлеше буларак гомуми тел белеме чикләрендә үсеш ала. 17–18 йөзләрдә гимназияләрдә, руханилар училищелары һәм семинарияләрендә «татар теле» предметы кертелә һәм системалы рәвештә фәнни нигездә өйрәнелә. Татар тел белеме фән буларак 18 йөзнең 2 нче яртысыннан С.Х.Хәлфин, И.И.Гиганов, А.А.Троянский хезмәтләрендә формалаша башлый. Алга таба ул Казан университетының Шәрекъ бүлеге галимнәре А.К.Казимбәк (Мирза Казимбәк), И.Н.Березин, И.И.Хәлфин, М.*Мәхмүдов* һәм башкаларның хезмәтләрендә үсеш ала. Казан университетының төрек-татар теле кафедрасында Россия тюркологиясенә нигез салына (19 йөз башы).

19 йөзнең 2 нче яртысында Каюм Насыйри, В.А.Богородицкий, Х.Ф.Фәезханов, Н.Ф.*Катанов* һәм башкаларның тел белеменә караган хезмәтләре нәшер ителә. К.Насыйриның фәнни эшчәнлеген яктырткан галимнәр беренче чиратта аны тел галиме дип атыйлар. Аның тел белеме тармаклары (лексикография, лексикология, терминология, фонетика, грамматика һ.б.) буенча эшчәнлеге В.Н.*Хангилдин*, Р.А.*Хәкимова*, Г.М.*Халит*, Ш.Г.*Рамазанов*, М.К.*Мөхәррәмов*, Ф.С.*Фасиев*, В.Х.*Хаков*, М.З.*Зәкиев*, С.М.*Михайлова*, М.С.*Мәһдиев*, Ә.Ш.*Юсупова* һ.б.ның хезмәтләрендә тикшерелә.

Татар лексикографиясендә сүзлекләр төзү юнәлешенә 19 йөз ахырында К.Насыйри тарафыннан нигез салына. 1878 елда аның — «Татарча-русча лөгать китабы»ның («*Татарско-русский словарь*»), 1892 елда «Русча-татарча сүзлек» китабының («*Полный русско-татарский словарь*») беренче басмалары дөнья күрә. Алар өстендә эшләгәндә галим русларга — татар телен,

татарларга рус телен өйрәтү максатын алга сөрә, шул рәвешле (шулай ук кыскача Россия тарихы белән таныштырып) ике халыкны үзара тагын да якынайтуга зур өлеш кертә. 1895–1896 елларда галимнең ике томлык «*Ләһҗәи татари*» хезмәте — татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге дөнья күрә. Аны төзергә алынганда К.Насыйри татарларга һәм башка кызыксынучыларга шул чор татар әдәби телен өйрәтү һәм татар әдәби телен лексик-стилистик җәһәттә баету бурычын куя. Сүзләрне аңлатуда ул төрле материал һәм чаралардан файдалана, берничә төрле алым (сүзләрне турыдан-туры татарча яки татарчалашкан ишләре яисә синонимнары белән аңлату; гарәп, фарсы сүзләре белән генә, яки алар белән татар сүзләрен дә аралаштырып тәрҗемә итү; татар, рус һәм гарәп сүзләре белән тәрҗемәләү; сүзнең анык синонимнары яки яраклы тәрҗемәләре табылмаганда аңлатмалар бирү; сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау, аларның кулланылган урыннарын күрсәтү өчен күп кенә мисаллар, иллюстрация материаллары файдаланылу) куллана.

В.Н.Хангилдиннең 1948 елда дөнья күргән «Каюм Насыйри. 1825–1945...» басмасында урнаштырылган «Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе» мәкаләсендә галим төзегән сүзлекләрнең татар әдәби теле үсеше һәм алдагы чорларда барлыкка килгән сүзлекләр өчен ышанычлы җирлек булу әһәмияте ассызыклана, аерым алганда, «Ләһҗәи татари» татар телен тарихи үсешендә өйрәнү юлында, аеруча аның лексика өлкәсен өйрәнү өчен бердәнбер тулы чыганак буларак бәяләнә. К.Насыйриның терминологик сүзлекләре исә (фәннең төрле тармаклары буенча кулъязмалар хәлендә сакланган латинча-гарәпчә биология терминнары сүзлеге, татарча-латинча-русча ботаника терминнары сүзлеге, татарча биология терминнары сүзлеге, русча-латинча-татарча ботаника терминнары сүзлеге, гарәпчә-татарча-латинча гомуми терминнар сүзлегенең башлангычы) татар әдәби телен лексик яктан нормалаштыру максатын күздә тота. К.Насыйри татар тел белеменең башка тармаклары юнәлешендә дә нәтиҗәле эшли. Фонетика һәм грамматика буенча «Кавагыйде китабәт, ягъни тасниф вә имля кагыйдәләрен бәян кыйлгучы бер яңа фәндер» (1892), «Әнмүзәҗ (Лисаныбызның сарыф вә нәхү кагыйдәләре бәянында») (1895) хезмәтләрен яза.

М.З.Зәкиевнең «Советская Татария» газетасында (1975) «Милләт теленең чишмә башында: Каюм Насыйриның тууының 150 еллыгына карата» һәм «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында (1976) «К.Насыйри һәм хәзерге милли татар теле формалашу» мәкаләләрендә галимнең милли телне камиләштерүдәге эшчәнлеген өч яссылыкта — милли тел формалашуның теоретик мәсьәләләре өлкәсендә тикшеренүләр, әдәби нормалар урнаштыруда катнашу, аларны гамәлгә ашыру юнәлешләрендә карарга тәкъдим итә, аның телнең милли лексика, орфоэпика, фонетика, морфология һәм синтаксис нормаларын эшләргә керешүенең сәбәпләрен — гомумхалык нормаларына якын яңа милли әдәби нормаларны булдыруга алынуының асылын барлыкка килүче милләт үсешенең әдәби телне гомумхалык сөйләм нормаларына якынайту ихтыяҗын тирән аңлауда күрә; аның һәркем өчен дә аңлаешлы гомумхалык телен өйрәнүдән гайре җәмгыятьнең киләчәк үсеше мөмкин түгел дигән фикерен ассызыклый, милли тел сүзлеген, составын ике (татар сүзләре һәм гарәп-фарсы алынмалары) катламга бүлеп, гомумтөркі тел тарафдарларына каршы

чыгып, мөстәкыйль татар теле тәгълиматын алга сөрүен, тел белеме өлкәсендәге хезмәтләрен югары бәяли, «Татар телен өйрәнү өчен гамәли кулланма» («Практическое руководство к изучению татарского языка», 1857) уку ярдәмлеге авторы Мөхәммәдгали Мәхмүдовны (1824–1891) исәпләмәгәндә, Каюм Насыйрины «милли татар телен фәнни әйләнешкә кертүнең пионеры» дип атый.

В.Х.Хаков К. Насыйри хакындагы хезмәтләрендә, аеруча 1976 елда нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Татар тел белемендә К.Насыйри традицияләре» мәкаләсендә, шулай ук «Тел — тарих көзгесе» китабының аңа багышланган өлешендә мәгърифәтченең тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеген ике юнәлештә — милли телнең фәнни-теоретик мәсьәләләрен тикшерү һәм әдәби тел нормаларын лексик, фонетик, грамматик яктан төрле аспектта гамәли юнәлештә үстерү һәм эшкәртү юнәлешләрендә кararга тәкъдим итә; Каюм Насыйриның әлеге фән үсешенә керткән өлешен, аерым алганда, аның «Әнмүзәж» әсәренең (аны «татар теленең XIX йөздәге иң яхшы грамматикасы» дип атый) һәм татар теленең тәүге «Ләһҗәи татари» аңлатмалы сүзлегенең алдагы чорларда яңа грамматикалар һәм сүзлекләр барлыкка килүгә этәргеч бирүен ассызыклый, галимнең традицияләренең белгечләрнең алдагы буыннары вәкилләре (Хөсәен Фәезханов, Габделгалләм Фәезханов, Габдеррахман Начиз, Мөхәммәтсәлим Өметбаев, Габдрахман Сәгъди, Мөхетдин Корбангалиев һ.б.) тарафыннан дәвам иттерелүен билгеләп уза.

М.С.Мәһдиев «Наука и религия» журналында (1975) дөнья күргән «Галим Каюм бабай» мәкаләсендә аталы мәгърифәтченең күпкырлы фәнни эшчәнлеген яктырта, Каюм Насыйри тарафыннан төзелгән тәүге фәнни грамматиканы, татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген, төрле сүзлекләрне, дөрес язу кагыйдәләрен дөньяга чыгарып җәмәгатьчелеккә җиткерүен гаять югары бәяли.

Ә.Н.*Хәйри* Каюм Насыйри хакындагы «Мәдәни җомга», «Заман–Татарстан», «Шәһри Казан» газеталарында басылган язмаларында нәкъ менә К.Насыйриның беренче булып гарәп язмасындагы 28 хәреф өстенә, татар теле үзенчәлекләрен искә алып, татар хәрефләре өстәп, татар әлифбасын камилләштерү мәсьәләсен күтәреп чыгуына игътибар юнәлтә.

Р.Ә.*Мостафин* «Кызыл таң» газетасының 1975 елгы 14 февраль санында Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулуга багышланган «Мирас итеп калдырган» мәкаләсендә галимнең милли телне эшкәртүе нәтиҗәсендә «җанлы татар теленә гражданлык хокукы бирүе»н ассызыклый.

Әд.: Мөхәррәмов М., Абдуллин Я. Күренекле татар галиме һәм демократы // Татарстан коммунисты. 1975. №5; Хаков В.Х. Традицияләр дәвамы (Каюм Насыйриның тууына — 150 ел) // Социалистик Татарстан. 1975. 14 февраль; Хаков В.Х. Тел — тарих көзгесе. Казан, 2003; Хангилдин В.Н. Каюм Насыйри грамматикаларында татар теле синтаксисы нигезләре // Совет әдәбияты. 1945. №2; шул ук. Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Хәйри Ә. Бер кулъязма эзеннән: Каюм Насыйриның тууына 160 ел тулу уңаеннан // Социалистик Татарстан. 1985. 14 февраль; шул ук. Милләтне нурландырган шәхес // Заман–Татарстан. 1995. 10 февраль; Закиев М.З. У истоков языка нации: К 150-летию со дня рождения Каюма На-

сыри // Советская Татария. 1975. 13 февраля; шул ук. К.Насыри и формирование современного татарского национального языка // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Фасеев Ф.С. Насыри и татарская терминология // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Хаков В.Х. Традиции К.Насыри в татарском языкознании. Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

И.Х.Хәлиуллин.

ТЕРЕГУ́ЛОВ Ибраһим Вәлиулла улы (29.05.1852, Уфа шәһәре – 22.11.1921, Төркестан АССРның Сәмәрканд шәһәре), педагог, ветеринария табибы.

1874 елда Казан ветеринария институтына укырга керә, уку дәверендә «Касыймия» мәдрәсәсендә рус теле укыта. Институтны тәмамлаганнан соң, *Казан татар укытучылар мәктәбендә* табигать белеменнән дәресләр бирә (1878–1912) (бүленеп, 1906–1908 елларда — Казан университеты студентлары испекторының ярдәмчесе). Шул чорда укытучылар мәктәбендә мөгаллим булып эшләгән Каюм Насыйри белән аралаша. Аерым алганда, Галимҗан *Акчуринның* «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат» хатирәсендә В.В.*Радловның* аны, шулай ук Каюм Насыйрины, Шаһбазгәрәй *Әхмәровны* шушы укытучылар мәктәбенә укыту эшенә чакыруы, аларның 7–8 ел үзара аралашуы хакында искә алына (кара: *Истәлекләр*).

1915 елдан — Мәскәү, 1916 елдан — Оренбург уку-укыту округларының татар мәктәпләре инспекторы, 1918 елдан — Оренбург губерна башкарма комитетында халык мәгарифенең мөселман бүлеге мөдире, бер үк вакытта, 1918–1920 елларда өч еллык педагогия курсларында укыта. 1921 елдан — Сәмәрканд педагогия институтында.

Терегулов тырышлыгы белән укытучылар мәктәбендә табигыять фәннәреннән белем бирү югары дәрәҗәдә оештырыла, укыту гимназияләр өчен ул татарчага тәрҗемә иткән уку ярдәмлекләре буенча алып барыла; татар телендә медицина, гигиена, авыл хуҗалыгына караган фәнни-популяр басмалар, аның үз хезмәтләре һәм тәрҗемәләре басылып чыга (алар табигыять фәннәренә караган татар лексикасын формалаштыруда мөһим роль уйныйлар).

Шәрекъ клубын оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе һәм аның идарәсенең беренче рәисе. А.Н.Островский һәм А.К.Толстой пьесаларын татар теленә тәрҗемә итүне һәм бастыруны оештыра (тәрҗемәчеләрнең берсе үзе дип фаразлана).

Хезм.: Су. Кыйраәт китабы. СПб., 1897; Татар нәхүсенең мохтасары. Казан, 1901; Бәрәңге, аның нәүгылары (сортлары) һәм аны үстерү. Казан, 1913; Кычу тугрысында. Казан, 1913.

Әд.: Әхмәтҗанов М. Галим-педагог Ибраһим Терегулов // Мирас. 1994. № 2; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Терегулов Ибраһимның 30 сәнәлек гыйльмиясенә ядкарь. Оренбург, 1908.

И.Х.Хәлиуллин.

ТӨХФӘТУ́ЛЛИН Гыйбадулла (1871, Казан губернасының Зөя өязе Югары Шырдан авылы (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы) — ?), Каюм Насыйриның авылдашы һәм аның турында хатирә авторы. 1945 елда фольклорчы Хәмит *Ярми* тарафыннан аңардан К.Насыйри турында истәлек язып алына һәм 1948 елда җыентыкта нәшер ителә.

Үзенең истәлегендә К.Насыйри белән бәйле вакыйгаларны түбәндәгечә

тасвирлый: «...Каюм абыйны иң беренче мәртәбәсендә мин Казанда күрдем. Мине авылдан әтиләре, аны Шырданга алып кайтырга, дип җибәргәннәр иде. Ул вакытта Каюм абый Бәдигъ мөәзин йортында тора иде. Мин пар ат җигеп, хәтерләмим инде, Каюм абый белән тагын да кемнәрнедер бергә утыртып, аларны кунакка алып кайттым. Авылга кайткач, аның белән очрашырга, утырдаш булырга туры килмәде, без ул чагында яшь идек әле. 3–4 ел үткәч, ул тагын да безнең авылга кайтты. Анысында инде миңа аны Казанга илтеп куярга туры килде. Каюм абый бик аз сүзле кеше иде. Юлда барганда да артык сүз сөйләшми, тик мин аның «балаларны укытырга кирәк, аларга салкын күз белән карау ярамый» дигән сүзен бик яхшы хәтерлим. Мин аның сүзен тоттым. Үзем укый алмадым, ләкин балаларны укытып, файдалы совет работниклары иттем...»



Г.Төхфәтуллин

Хатирәсендә ул шулай ук К.Насыйрины Казан урамында еш күрүе, аның һәрвакыт җәяү йөрүе, сәгатьнең һәр минуты аның өчен кадерле булу хакында искә ала. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ТУКА́Й (Тукаев) Габдулла Мөхәммәтгариф улы (26.04.1886, Казан губернасының Казан өязе Кушлавыч авылы – 15.04.1913, Казан), шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче, публицист, яңа татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе.

Мулла гаиләсендә дөньяга килә. Дүрт яшьтән ятим кала. Үсмер чагы Җаек (Уральск) шәһәрендә уза, шунда 1895–1907 елларда «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә белем ала, аның каршындагы рус мәктәбенә йөри, рус мөхәррирләре ижаты белән кызыксынып китә. Шушы чорда басмаханәдә эшли, Җаектагы алдынгы фикерле яшьләр белән аралаша. Беренче ижади тәҗрибәләре 1902–1904 елларда башлана. 1905 елгы үзгәрешләр йогынтысында чыга башлаган «Фикер», «әл-Гаср әл-җәдид», «Уклар» газета-журналларында эшли. Тәрҗемә белән шөгыльләнә башлый, 1906–1907 елларда «әл-Гаср әл-җәдид» журналында «Энҗе бөртекләре» исеме астында 77 тәрҗемә мәсәл бастырып чыгара.

1907 ел ахырында, солдатка каралу уңае белән, туган ягына кайта, Казанда яши. Фатих Әмирхан, Галиәскәр Камал, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй һ.б. белән дустанә һәм әдәби мөнәсәбәтләр урнаштыра. Казанда шагыйрь күңел күтәренкелеге, зур өметләр белән эшли. Үз идеалларына хезмәт итү, хөр, азат милли матбугатны үстерү теләге белән яна. 1908–1909 елларда Г.Камал белән бергә «Яшен» сатирик журналын чыгара, 1910 елдан «Ялт-йолт» журналында эшли, гомеренең ахырына кадәр аның рухландыручысы, җитәкчесе булып кала.

Г.Тукайның беренче шигырьләрендә мәгърифәтчелекне һәм халыкның белем дәрәҗәсен («Голүмең бакчасында», 1905), милләтнең мәдәниятен үстерү («Шигырь», 1905), социаль үзгәрешләргә чакыру («Хөррият хакында», 1905), татар җәмгыятен яңарту («Дустларга бер сүз», 1905; «Иттифакъ хакында», 1905) идеяләре чагыла. Мәгърифәтчелек юнәлеше татар әдәбияты

өчен традицион булган «Алла — кеше» мөнәсәбәтен үзәккә куйган дөнья сурәтен үзгәртүгә этәргеч бирә.

Каләмгә мөрәҗәгать кебек язылган «И, каләм!» (1906) шигырендә лирик герой үзенең милләт һәм мөселманнар вәкиле булуын ассызыкласа да, шигырьдәге каләм — милләт мөнәсәбәтен үзәккә куя. Урта гасырлар шагыйрьләре өмет тулы карашларын Аллага төбәгән кебек, милләтнең бер вәкиле булган лирик геройның киләчәккә ышанычы да каләм белән бәйләнгән. Моннан тыш милләт хәлен Европаның үсеш дәрәҗәсе белән чагыштыру, соңгысының язма сүз ярдәмендә «күкләргә кадәр» күтәрелүен әйтү шигырьдәге каләмнең дәрәҗәсен тагын да арттыра.

Шундый ук омтылышлар аның публицистикасында да чагылыш таба. Әйтик, «Хиссияте миллия» (1906) мәкаләсендә ул болай ди: «Милләт образованный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ... Безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйларына сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, бардакханәдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ». «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» (1906) язмасында болай дип дәвам итә: «...без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, гәзитә мәрвәхәләре [веерлары] илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихад вә иттифакъ сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карасын, гакылын җыйсын». Г.Тукайның әлеге чор сатирик иҗатында халыкның иҗтимагый-мәдәни хәлен тәнкыйтьләү мотивы өстенлек ала. Тәнкыйть угы наданлыкка («Япония мөселман идәчәк голяма нәрәдә?», 1906), әхлаксызлыкка («Кечкенә генә бер көйле хикәя», 1906; «Хатирәи «Бакырган», 1906), дини фанатизмга («Мәритләр каберстаныннан бер аваз», 1906; «Сорыкортларга», 1906; «Пыяла баш», 1906) каршы юнәлтелгән. Демократик үзгәрешләргә чакыручы шагыйрьнең шигырьләрендә әкренләп гражданлык һәм сәяси карашы кискенләшә («Государственная думага», 1907; «Китмибез!», 1907). Г.Тукай халыкның бүгенгесе караңгы, киләчәге һәркемнең ныклыгына һәм активлыгына бәйле язмышы турында уйлана. Вакытны бушка, нәтиҗәсез уздыру хакындагы фикере сәясәтчеләргә, сәүдәгәрләргә, руханиларга, шәкертләргә атап әйтелгән гаепләүләрендә чагыла. Шагыйрь хатын-кызларга ирләр белән тигез хокуклар даулый.

Шигырь төзелешендә милли традицияләрне барлап, шулай ук рус һәм Европа әдәбиятлары йогынтысында гаруздан силлабикага күчә; лирик геройның гражданлык кичерешләрен сурәтләгәндә чикли торган шәрекъ жанрлары — газәл, мәдхия, мәрсия, касыйдәнең кайбер билгеләре аның әсәрләрендә җуелып, шигырьләре Көнбатыш әдәби жанрлар системасында кабул ителә. Шагыйрь җитди рәвештә халык өслүбе, фольклор традицияләре белән кызыксына. Әдип иҗатының халык иҗатына якынаюы шигъри әсәрләре теленең чистаруына китерә, шигырьләре гарәп-фарсы һәм төрек алынмаларыннан котыла. Романтик лирик герой милләткә хезмәт итүгә омтыла. Иҗат темасына багышланган шигырьләрендә шагыйрьнең бөек миссиясе — халыкны алгарыш юлында җитәкләү омтылышы раслана («Бер татар шагыйренең сүзләре», 1907). Рухи хөр-

лек, тышкы шартларда ирекле булуга дан җырлап һәм социаль проблемаларга игътибарын юнәлтеп, Тукай үз язмышының халык язмышыннан аерылгысызлыгын тирән тоеп иҗат итә («Көз», 1906; «Хөрриятә», 1907; «Теләнче», 1907). Фольклордан килгән образлар, детальләр, сюжетлар балалар өчен язылган әсәрләрендә мул кулланыла («Шүрәле» әкият-поэмасы, 1907). Кайбер шигырьләрендә туган җиргә мәхәббәт туган телгә мәхәббәт, табигать гүзәллегенә һәм гадәти көнкүрешнең гади матурлыгына соклану хисләре белән бәйле («Пар ат», 1907; «Туган җиремә», 1907 һ.б.)



Г.Тукай

Г.Тукайның сатирик таланты үсә, шул юнәлештәге шигырьләрендә ул үзләрен милли мәнфәгатьләрне кайгыртучылар дип тәкъдим иткән икейөзле, әхлаксыз динчеләрдән көлә («Ысулы кадимче», 1908; «Милләтчеләр», 1910; «Яшьләр», 1910; «Казан вә Казан арты», 1912 һ.б.).

Казан чоры (1907–1913) — аның иҗатының чәчәк ату дәвере, анда романтик мотивлар көчәя, ул шигъриятта фәлсәфи тирәнлеккә ирешә һәм үзен халык тормышының җырчысы итеп таныта. Шигырьләрендәге мәгърифәтчел караш үзгәрә: ул фәлсәфи нәтиҗәләрнең сәбәбенә әверелә, алгы планга милләткә, халыкка хезмәт итү мотивы чыга.

Татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, Г.Тукай махсус рәвештә халык авыз иҗатының эстетик принципларын, аның язма әдәбият белән бәйләнешен өйрәнүгә керешә. 1910 елда танылган Шәрекъ клубында шагыйрь «Халык әдәбияты» дигән лекция укый, «Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!» шигарен күтәрә. Үз иҗатында халык әкиятләренең сюжет схемаларын («Шүрәле», 1907; «Су анасы», 1908; «Кәҗә белән сарык хикәясе», 1910 һ.б.), халыкның дөньяга карашы һәм дөньяны чагылдыру үзенчәлеген («Милли моңнар», 1909), татар фольклорына хас образларны һәм детальләрне, сурәтләү чараларын («Пар ат», 1907; «Эштән чыгарылган татар кызына», 1909) файдалана, халык җырларына охшатып стильләштерә («Авыл җырлары», 1908).

Г.Тукай әдәби тәнкыйть, публицистика, балалар әдәбияты өлкәсендә актив эшли. 1909 елда автобиографик характердагы «Исемдә калганнар» әсәрен иҗат итә. Әсәрдә бала чагында Кушлавыч авылындагы Бәдри абзый гаиләсендә яшәгән вакытта Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» хезмәтенә тап булуы, аны йотлыгып укуы һәм аның тәэсире хакында: «Кич белә китаплар актарганда, кулыма «Фәвакиһел җөләса» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам, фәкать мин Кырлайда чакта тик «Газизә» вә «Сөбател гажизин»нәр генә укыганга, бу китаптагы оят сүзләргә гажәпләнәм вә, китапта шундый сүзләр дә була микәнни дип, үземә сөаль бирә идем. Кайчакта мин, шул «Фәвакиһел җөләса» тәэсире илә, Гайшә абыстайның кер юган җиренә — кара өйгә барып, аның белән кычкырыша торган идем», — дип искә ала. Ибраһим *Нуруллин* фикеренчә, «сүз К.Насыйри китабының соңгы бүлеге турында бара. Биредә Г.Кандалыйның өч шигъри әсәре, берничә бәет һәм күп санда халык җырлары, мәкаль һәм табышмаклар тупланган. Бәет һәм шигырьләр көндәлек тормыштан алып саф татарча язылган булулары белән

баланың күңелен җәлеп итә. Җырлар исә Габдуллага яңа дөнья ачкан кебек булалар. Җырның дәрәҗәсе аның күзендә, һичшиксез бермә-бер үсеп китә».

Әсәр.: Әсәрләр: 5 томда. Казан, 1985–1986; Избранное: В 2 т. Казань, 1961.

Әд.: Габдулла Тукай. Энциклопедия. Казан, 2016; Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы. Казан, 2002; Заһидуллина Д.Ф. Тукай Г.М. // Татар энциклопедиясе. Казан, 2019. 6 т. 1 кис.: Тә–Ч; Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты // Габдулла Тукай (1886–1913). Казан, 1966; шул ук. Габдулла Тукай. Казан, 1979; Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Тукая. Казань, 1964.

Д.Ф.Заһидуллина.

ТУКТАМЫ́ШЕВ Наил Кадыйр улы (03.04.1954, Татарстанның Чүпрәле районы Иске Чокалы авылы), педагог, математик, физика-математика фәннәре кандидаты (1981), педагогика фәннәре докторы (2001), профессор (2001), РФнең Югары белем бирү мактаулы хезмәткәре. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2013).

Казан университетының механика-математика факультетын тәмамлый (1976). Казан архитектура-төзелеш университетының югары математика кафедрасында эшли, 2004 елдан — гомуми инженерлар әзерләү факультеты деканы.

Хезмәтләре кырый мәсьәләләргә, югары уку йортларында ике телдә укытуга күчүнең социаль-педагогик нигезләрен эшләүгә карый. Математика, механика, педагогика буенча фәнни хезмәтләр авторы. Аның тарафыннан татар телендә математика буенча терминология нигезләре һәм югары уку йортында билингваль укытуга күчү концепциясе эшләнә, татар



Н.К.Туктамышев

телендә укыту өчен математика фәннәре буенча методик комплекслар төзелә.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк «Югары уку йортларында татар телендә укытуның теоретик һәм гамәли нигезләре (Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты мисалында)» хезмәте өчен бирелә. Әлеге хезмәттә Казан архитектура-төзелеш университетының татар телендә укыту буенча методик кабинеты һәм аның иң актив әгъзалары — методик кабинет мөдире Р.Ә.*Шакиржанов*, профессор А.З.*Камалов* белән бергә Н.Туктамышевның татар телендә югары белем бирүне концептуаль һәм фәнни-методик яктан тәэмин итү, Казан архитектура-төзелеш университетында татар телендә укытуны тормышка ашыру, уку-укыту–методик комплекслар төзү, татар телендә укытуны мәгълүмати һәм терминологик яктан тәэмин итү буенча күп еллар дәвамында алып барылган эш нәтиҗәләре күрсәтелә.

2003–2017 елларда — «Мәгариф» татар милли мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләре ассоциациясе» оешмасы рәисе. Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы законны гамәлгә ашыру мәсьәләләрен хәл итүдә актив эш алып бара.

«Казанның 1000 елыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Решение задачи Гильберта для кольца в особом случае и его применение к одной задаче взрыва // Математические заметки. 1999. Т. 8, вып. 1; Социально-педагогические основы преподавания в высших технических школах в условиях билингвизма. Казань, 2000; Математик фи-

зика тигезләмәләре: уку кулланмасы. Казан, 2003.

Ф.Г.Камальтдинова.

ТҮНТӘРИ́ Мөхәммәтнәҗип (Шәмсетдинов Мөхәммәтнәҗип Шәмсетдин улы) (1862, Вятка губернасының Малмыж өязе Түнтәр авылы — 1930, фаразланганча, Казан), педагог, дин белгече һәм эшлеклесе.

Түнтәр мәдрәсәсендә әтисендә, шулай ук Казанда («Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган булуы ихтимал) укый. 1890 елдан — Түнтәр мәчетенең имамы; Галимҗан Баруди ярдәме белән авылда Ишмөхәммәт Динмөхәммәтовның кадимчелек мәдрәсәсенә каршы җәдитчелек нигезендә мәдрәсә оештыра. 1911 елда И.Динмөхәммәтов әләге белән «Буби эше» буенча кулга алына, 1912 елда имам вазифасыннан читләштерелә. 1913–1917 елларда — Казанда «әд-Дин вә әл-Әдәб» журналы хезмәткәре. 1917–1918 елларда (1919 елда булырга мөмкин) — Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте хезмәткәре. 1918 (1919) елдан — Түнтәр авылының 1 нче мәхәлләсе имам-хатибы, мәдрәсәне саклап калырга тырыша. 1930 елда кулга алына, 10 елга хөкем ителеп, Төньяк крайга сөргенгә җибәрелә; төрмәдә үлә.

Дин белеменә, Түнтәр авылы тарихына караган хезмәтләр авторы. Түнтәринең басылмаган кулъязмалары Сәет Вахиди тарафыннан сакланган, ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында саклана.

Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри турында истәлек яза, ул беренче мәртәбә «Шура» журналында (1913) басылып чыга. Аннан соң Фатыйма *Ибраһимова* тарафыннан «Әдәби мирас»ның 3 нче китабында дөнья күрә. Түнтәри К.Насыйри турында язган истәлегендә мәгърифәтченең бер хикәясен диварга куяр өчен бөтен табакка бастырган нөсхәсен күрсәтүен әйтә һәм әдипнең сүзләрен китерә: «Бу рәвештә бастыруымның сәбәбе — халык китапны күп укымый, диварга куйганда иректсез укырлар, күзләре төшәр. Бер кеше угылыны укырга мәхәббәт куйдыра алмый гаҗиз улгач, бер бүлмә диварына дәресләр вә китаплар яздырып, угылыны шул бүлмәгә куйган. Бала бүлмәнең һәр тарафына караса, дәрес китаплары күргән вә ахырында укырга керешеп, шуннан уку юлына кереп киткән...» К.Насыйриның әлеге язмасыннан М.Түнтәри гыйлемле булу өчен китап укуны һәркем үз алдына максат итеп куярга тиеш, ә балаларда китапка мәхәббәт уяту өчен төрледән-төрле кызыксындыру чараларын булдыру мәслихәт дигән нәтиҗәгә килә. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Хәдүс галәмгә игътикад җә hәтеенен бер назар. Казан, 1900; Төзкире әт төбь инфи-л-вагаз вә-т-тәгълим китабының 1 нче кисәгенең тәрҗемәсе. Казан, 1913; Исламда хатыннар хокукы. Уфа, 1917; Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләрем // Әдәби мирас. 3 нче китап. Казан, 1996; Мөхәммәтнәҗип хәзрәт язмасы // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2003. №1/2.

Ф.С.Гыйниятуллина.

У

УКМАСЫЙ (Зәбиров Миргазиз Габделкаюм улы) (14.06.1884, Казан губернасының Лаеш өязе (хәзер Татарстанның Балык Бистәсе районы) Кече Укмас авылы – 1948, Казан), шагыйрь, укытучы, дин эшлеклесе; Габдулла Тукай шигърият мәктәбен дәвам итүче буларак билгеле. Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша (1914–1918).

Башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, 1908 елга кадәр Илә-бәр, Сатыш (хәзер Саба районы), «Мөхәммәдия» (Казан) мәдрәсәләрендә укый; «Яшерен әдәби түгәрәк» һәм шәкертләрнең «әл-Ислах» яшерен сәяси оешмасы әгъзасы. 1907–1914 елларда Саратов губернасының Татар Кынадысы авылында, Казакъстанның Акмулла шәһәрендә укыта. 1923–1925 елларда туган авылында мулла була, игенчелек белән шөгыльләнә. 1931 елда кулга алына, шартлы рәвештә 8 елга лагерьларга хөкем ителә. Соңыннан Яшел Үзән һәм Казан шәһәрләрендә яши.

Беренче шигырьләрен 1905–1907 елларда «Казан мөхбире», «Бәянелхак», «Азат», «Йолдыз» һәм башка газеталарда бастыра. «Хатирә, яки Дустларыма сүзләрем» (1906), «Алданма кызыл алмага» (1907), «Миргазиз Укмасый шигырьләре» (1909), «Өмид йолдызым» (1912) шигырь җыентыклары, «Хәлифәлек өчен көрәш» (1917 елда «Сәйяр» труппасы куя) пьесасы, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан турында истәлекләр, әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы.

«*Совет әдәбияты*» журналының Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган 1945 елгы 2 нче санында «Каюм абзый Насыйри» дип аталган истәлеге дөнья күрә. Әлеге язмада мәгърифәтче белән очрашуы хакында бәян ителә. Анда авторның, беренче мәртәбә Укмас авылы тегермәненә арыш тарттырырга төшкәч, К.Насыйриның тәрәзә төбендә яткан китабына тап булуы, аны, өенә алып кайтып, башта эти-әнисенә укытуы, соңрак аның авыл халкы арасында кулдан-кулга күчеп йөрүе, әлеге китапны кулыннан төшермичә, кич белән кызлар, егетләр янына алып барып укуы, аларның, Казанга барып эзләсәләр дә, мондый китапны таба алмаулары хакында искә алына.

1898 елда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлагач, К.Насыйриның календарьлары һәм башка әсәрләре белән танышуы, мәгърифәтче янына баргалап йөргән шәкертләрнең кичерешләре йогынтысында 1901 елда үзенең дә аның белән очрашуы, галимнең үз-үзен тотышыннан, ярдәмчеллегеннән, тирән фикерләреннән алган тәэсирләре белән уртаклаша. Шагыйрьнең хатирәсендә К.Насыйриның фатирындагы җиһазларга, аның киемнәренә, анда эшләүче йомышчы малайларга, галимнең китаплар төпләвенә игътибары җәлеп ителә, К.Насыйриның аз сүзле булуы,

үзе белән салкын гына сөйләшүе искәртелә. К.Насыйри Укмасыйга рус телен өйрәнү кирәклеге турында: «...Безнең Ватаныбыз руслар белән бергә, аларда гыйлем зур, без файдалана белмибез, мәдрәсәләрдә рус теле булмау бик зур кимчелек, безгә гарәп теле түгел, рус теле кирәк, русча укырга тырыш, кирәкле белем шунда, энем», — дип әйтә.



М.Г.Укмасый

Моннан тыш Укмасый мәдрәсәдә К.Насыйриның «Фәвакиһел җөләса», «Хәвасе нәбатат» һәм башка китапларының һәр шәкерт кулында кадерләп саклануын, мәгърифәтче вафат булгач, шәкертләрнең кайгыруларын, аны җирләргә баруларын ассызыклый, шул заманнарда татарлар арасында дини фанатизм бик көчле һәм аң-белем дәрәҗәсе түбән булу сәбәпле, татар байларының, галимне динсезлектә гаепләп, аның эшчәнлегенә тиешле бәя бирмәүләре хакында нәтиҗә ясый. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Чыг.: Каюм абзый Насыйри (истәлек) // Совет әдәбияты. 1945. № 2; Сайланма әсәрләр. Казан, 1958.

Әд.: Рәми З. Авыр язмышлы шагыйрь // Татарстан. 1994. № 5–6.

Ф.С.Гыйниятуллина.

УНДҮРТЕНЧЕ́ ТАТА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ, Һади Атласи исемендә, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми урта белем бирү муниципаль бюджет уку йорты. Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә урнашкан. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2009).

1992 елда татар мәктәп-гимназиясе буларак ачыла. 1996 елда Һ.Атласи музее оештырыла, янкорма төзелә. 1998 елда 14 нче татар гимназиясе итеп үзгәртелә. Уңышлы рухи-әхлакый һәм патриотик тәрбия эшчәнлеге өчен Һ.Атласи исеме бирелә (2012). Укыту процессы 20 сыйныфта өч дәрәҗәдә алып барыла: 1 нче дәрәҗә — башлангыч белем (1–4 сыйныфлар: барлыгы 8 сыйныф), 2 нче дәрәҗә — төп гомуми белем (профиль алды әзерлеге: 8 сыйныф), 3 нче дәрәҗә — урта гомуми белем (технологик һәм психологик-педагогик профиль буенча укыту: 4 сыйныф), шулай ук өстәмә белем бирелә; 25 педагог эшли.



Ундуртенче татар гимназиясе.

Эшчәнлегендә татар халкы мәдәниятенә карата хөрмәт, милли үзаң һәм башка халыкларның гореф-гадәтләренә, мәдәниятләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә, укучыларның иҗади һәм оештыру сәләтләрен, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга һәм үстерүгә, сәламәтлекләрен нык тытуга, талантлы укучыларны ачыклап, аларның сәнгати-эстетик, әхлакый һәм интеллектуаль үсешенә, һөнәр сайлавына һәрьяклап ярдәм итүгә, шәхес, илнең актив гражданнары буларак формалашуы өчен зарури шартлар тудыруга һ.б.га юнәлеш тота. Дәрестән тыш эшчәнлектә гражданлык-патриотик юнәлештә — «Ва-

тан каһарманнары көне», «Билгесез солдат көне», Җиңү көнендә онлайн рәвешендә — «Үлемсез полк», «Батырлык дәресләре»; спорт-сәламәтләндерү юнәлешендә — «Сәламәтлек атналары», «Минем хокукларым — минем бурычларым» түгәрәк өстәлләре һәм башка чаралар зур урын алып тора.

Гимназиядә үзешчән сәнгатькә зур игътибар бирелә. «Балачак иле» хореография коллективы — шәһәрдәге әйдәп баручы мәктәп коллективларының берсе. Студия балалары ел саен шәһәр хореография конкурсларында җиңүгә ирешәләр, «Без бергә» республика конкурсында 1 нче урынны яулыйлар. Коллектив репертуарының нигезе татар һәм рус халык биюләреннән гыйбарәт. «Татар сүзе» республика конкурсында, «Неопалимая купина» бөтенроссия конкурсында, «Шаян ТВ», «Мирас — Татарстан Республикасының мәдәни мирас объектлары балалар күзлегеннән» республика конкурсларында 2 нче урынны яулыйлар.

К.Насыйри исемендәге бүләк Татарстан халыкларының мәдәниятләре, традицияләре нигезендә милли мәгариф үсеше һәм патриотик тәрбия өлкәсендә ирешкән казанышлары өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

УНЫНЧЫ́ ГИМНА́ЗИЯ («Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының 10 нчы гимназиясе»), ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының гомуми белем бирү муниципаль бюджет уку йорты. Татарстанның Яшел Үзән шәһәрендә урнашкан. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләгә лауреаты (2014).

1944 елда мәктәп буларак нигезләнә. 1976 елдан — Яшел Үзән шәһәренең 10 нчы урта мәктәбе (яңа бинада). 1995 елдан — 10 нчы урта мәктәп-гимназия, 1998 елдан — 10 нчы гимназия, 2011 елдан — хәзерге исемдә (Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының 10 нчы гимназиясе). 2024 елда 1084 укучы белем ала, 54 педагог эшли.

Эшчәнлегендә татар халкы тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт, туган төбәкнең һәм анда яшәүче халыкларның традицияләренә, мәдәниятенә һәм әдәбиятына ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлеш тота. Ел саен уку йортында үсеп килүче буында татарларның, русларның, Идел буенда яшәүче башка халыкларның мәдәниятенә һәм традицияләренә карата кызыксыну тәрбияләү максатында «Мәдәниятләр диалогы», «Күптөрле Татарстан», «Без төрле, ләкин без бергә!» фестивальләре үткәрелә. Сыйныфтан тыш эшчәнлек «Беренче театр» студиясе, «Гөрләвек» газетасы, «Мирас» халык биюе түгәрәге, «Әдәби ишегалды» («Тукайны укыйбыз») түгәрәге тарафыннан башкарыла. «Милли педагогика» проекты кысаларында ата-аналар җыелышларында системалы рәвештә атаклы мәгърифәтчеләрнең хезмәтләре пропагандалана.

1995 елдан Каюм Насыйри исемендәге этнография музее хезмәт күрсәтә, ул фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. 2002 елдан гимназия җирлегендә К.Насыйри исемендәге халыкара фәнни-гамәли конференция уздырыла, анда Идел буе республикаларыннан, Россия Федерациясенең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән (Төркия, Кытай, Кыргызстан, Казакъстан) килгән вәкилләр катнаша. Укучылар һәм аларның ата-аналары белән бергә музейларга, К.Насыйриның тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле урыннарга (Олы Ачасыр, Кече Шырдан авыллары, Казан һ.б.) бару

оештырыла. Даими рәвештә К.Насыйриның туган көне билгеләп үтелә. Гимназия республика мәктәп музейлары конкурсында призга лаек була, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының мактау грамоталары белән бүләкләнә.

К.Насыйри исемендәге бүләк Татарстан халыкларының мәдәниятләре, традицияләре нигезендә милли мәгариф үсеше өлкәсендә ирешкән казанышлары өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

УРАЗМА́НОВА Рәүфә Кәрим кызы (22.02.1936, Удмурт АССРның Можга шәһәре), этнограф, тарих фәннәре кандидаты (1968). ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1984), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003).

Казан университетын тәмамлый (1959). 1964 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1993 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты), 1997 елдан — ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында (1993–2000 елларда — этнология бүлеге мөдире).

Хезмәтләре татар халык бәйрәмнәрен, гаилә гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнүгә карый. Каюм Насыйри турында мәкалә авторы. 1976 елда рус телендә нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Каюм Насыйри — этнограф» («Каюм Насыри как этнограф») мәкаләсендә галимнең татарларда беренчеләрдән булып Казан губернасының Зөя һәм Цивильск өязләре авылларында йөреп чыгып, шәхсән үзе җентекләп теркәгән ышанычлы материаллар нигезендә үз халкының тормышын һәм көнкүрешен тәфсилләп, объектив рәвештә бәян итүен билгеләп



Р.К.Уразманова

уза, 1880 елда аның «*Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*» фәнни журналының 6 нчы томында дөнья күргән «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» («*Поверья и обряды казанских татар*») язмасын анализлый. Халык авыз иҗатын барлауга һәм туплауга багышланып, Петр *Поляков* белән автордашлыкта шул ук журналның 16 нчы томында һәм аерым китап рәвешендә басылган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» хезмәтен этнографик күзлектән чыгып югары бәяли.

Медаль белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыри как этнограф // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Современные обряды татарского народа. Казань, 1984; Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX – нач. XX вв.). Казань, 2001.

И.Х.Хәлиуллин.

УРМАНЧЕ́ Бакый (Габделбакый) Идрис улы (10.02.1897, Казан губернасының Тәтеш өязе (хәзер Татарстанның Буа районы) Күл Черкене авылы – 06.08.1990, Казан), югары һөнәри белем алган беренче татар рәссамы, нәкышьче, сынчы, педагог; профессиональ татар нәкышенә нигез салучыларның берсе. ТАССРның һәм РСФСРның халык рәссамы (1960, 1982), ТРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1967).

Башлангыч белемне өендә ала. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен-

дә укый (1907–1914). 1915–1916 елларда Тамбов губернасының Шача өязе Татар Тарханы мәктәбендә укыта. 1916–1917 елларда — Россия армиясендә, беренче рәсем һәм нәкышь дәресләрен Казакъстанда хезмәт иткәндә, андагы австрияле хәрби әсирләрдән ала. 1917–1919 елларда — Вятка губернасының Глазов шәһәрендә һәм Казан губернасының Тәтеш шәһәрендә мәгариф халык комиссариаты инструкторы, бизәү эшләре белән шөгыльләнә (бәйрәм демонстрацияләре, клублар, мәктәпләр).



Б.Урманче

1919–1920 елларда Казан ирекле сәнгать остаханәләрендә нәкышьтән — Тимофеевта, скульптурадан — Г.А.Козловта, графикадан Н.С.Шикаловта белем ала. Бер үк вакытта Казандагы Республиканың Запастагы Армия штабы сәяси бүлегендә һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә эшли; ул бетерелгәннән соң (1920), Мәскәүгә Революцион хәрби советка күчерелә. 1920–1926 елларда Мәскәү Югары сәнгать-техника остаханәләренең (ВХУТЕМАС) берьюлы ике бүлегендә — нәкышь (С.В.Герасимовта һәм А.В.Шевченкода) һәм скульптура (Б.Д.Королёвта) бүлекләрендә укый. Аларны 1926 елда тәмамлаганнан соң, Казан сәнгать-театр техникумында укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли, керәч остаханәсен оештыра. Талантлы шәкертләр әзерләп чыгара (Мортаза Абдуллин, Мөхәммәтша Кәримов, Гата Йосыпов, Шакир Мөхәммәтҗанов, Марат Рахманкулов, Мәэмүн Сутюшев һ.б.). 1920 елларда Татар мәдәният йортында сәнгать секциясен җитәкли, гарәп графикасы шрифтын камилләштерү комиссиясе эшендә катнаша.

Иҗатының чишмә башы — татар җәдитчелеге, Европа нәкышь алымнарын үзләштерү белән бәйле. 1920 елларда станлы нәкышь һәм китап иллюстрацияләү өлкәсендә эшли. Бу чорда иҗат ителгән «Сепаратор янында», «Бикбулатов портреты» (икесе дә — 1927), «Көймәләр кичүендә» (1928), «Татар хатын-кызы», «Җилкәнле көймәләрдә йөрү», «Сары күлмәкле кыз» (барысы да — 1929) һәм башка картиналары совет һәм татар нәкышенең алтын фондына кергән.

Казан чорындагы (1950 еллар ахырыннан соңгы) җитлеккән һәм күпкырлы иҗаты сынлы сәнгатьтә һәм, тулаем алганда, республиканың мәдәнияте үсешендә яңа бер баскыч буларак бәяләнә. Әйдәп баручы скульптор (100 дән артык әсәр авторы). Татар дөньясындагы күренекле шәхесләрнең сынын тарихта мәңгелеккә калдырган рәссам. 20 йөзнең 2 нче ярты сы портрет сәнгатендә татар мәдәнияте һәм сәнгатенең танылган эшлеклеләре портретларының күләмле галереясын төзи. Скульптур портреттагы образ поставангард алымнары (шартлылык, декоративлык, стильләштерү, нәфис гипербола һ.б.) белән гәүдәләндерелгән, вакыт чикләрен белмәүче, тарихи, фәлсәфи-әхлакый, этномилли картиналарның тагын да киңрәк контекстын тәшкил итүче образлы эчтәлек тудыра. Урал мәрмәреннән, бронзадан, гипстан татар мәдәнияте эшлеклеләре Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри һ.б.ның портретлар галереясын (бюстлар, ярым-фигуралар) иҗат итә.

Каюм Насыйриның 2 скульптур портретын ясый (гипс һәм мәрмәрдән, икесе дә — 1970). Рәссам бу әсәрләрендә тирән белемле, үз чоры өчен алдынгы карашлы, мәгърифәт нуры чәчеп торучы образ тудыра. К.Насыйриның төрле өлкәләргә караган белем иясе, кыю фикерле, үз идеяләренә тугрылыклы шәхес булуын гипс һәм мәрмәрдә зур һөнәри осталык белән күрсәтә. Уйчанлык һәм тәвәкәллек, ачу





Б.Урманче. «Каюм Насыйри». Гипс. 1970; «Каюм Насыйри». Мәрмәр. 1970.

һәм үпкәле киная — барысы да шушы скульптур портретларда ачык чагыла. Әлеге сыйфатлар аерым-аерым да, шулай ук бер-берсен тулыландырып та бербөтен образ тудыралар. Мәрмәрдән ясалган скульптур портрет — Казандагы Бакый Урманче, гипстан ясалганы Казан федераль университеты музейларында саклана.

100 дән артык күргәзмәдә (1934 елдан), шул исәптән 1930 елларда Мәскәү рәссамнары күргәзмәсендә, Алма-Ата, Караганда һәм башка шәһәрләрдә казакъ рәссамнарының республика күргәзмәсендә (1942–1953), халыкара совет сынлы сәнгате күргәзмәсендә (Дәһли, Калькутта, Бомбей, 1952), «Зур Идел» күргәзмәсендә (1980 елдан) катнаша.

Әсәрләре Россиянең 20 дән артык музеенда, шул исәптән ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТРның Милли музеенда саклана.

Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр белән бүләкләнә. Казан шәһәренең мактаулы гражданы исеменә лаек була (1987).

Хезм.: Балалар сәнгате хакында ата-аналар, тәрбиячеләргә ни белергә кирәк? М., 1924; Татарстанның сынлы сәнгате // Совет әдәбияты. 1960. № 10; Из творческой работы // Искусство. 1936. № 1.


Әд.: Вәлиева-Сөләйманова Г.Ф. Урманче Б.И. // Татар энциклопедиясе. Казан, 2019. 6 т. 1 кис.: Тә-Ч. Бакый Урманче. Живопись. Графика. Скульптура. Декоративно-прикладное искусство. Казань, 2012; Баки Урманче и национальная художественная культура. Казань, 2008; Баки Урманче и татарская культура. Казань, 2005; Духовный мир Баки Урманче. Казань, 2005; Новицкий А. Баки Урманче. Казань, 1994.

Ф.Г.Камальтдинова.

УРТА́ ҺӘМ ЮГАРЫ́ БЕЛЕ́М БИРҮ́ СИСТЕМАСЫНДА́ ТАТА́Р ТЕЛЕНДӘ́ ҮКЫТҮ́: ТАРИ́Х, ЗАМАНЧАЛЫ́К ҺӘМ АЛГАРЫШЛА́Р, кара: «*Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы*».

«УТЫ́З ВӘГА́ЗЬ», дини китап. Эчтәлеге үгет-нәсихәттән гыйбарәт булган дидактик жанрда Каюм Насыйри тарафыннан гарәп телендә язылып, 1888 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә.

Кереш өлешеннән күренгәнчә, китап К.Насыйриның атасы Габденнасыйр бине мулла Хөсәен тарафыннан языла башлап, үлгәндә уллары Габделкаюм белән Габделкавига язып тәмам итүне васыять итеп калдырган була. К.Насыйри язып төгәлли һәм үз акчасына бастырып чыгара. Китапның ахырында татар телендә түбәндәге сүзләр китерелгән: «Әлхәмделилләһ раббелгаләмин, «Утыз вәгазь» тә-



К.Насыйри. «Утыз вәгазь». Казан, 1888.

мам. Рамазан кичәләрендә вә гайре вакытларда вәгазь әйткүче имамнар өчен мөгътәбәр китаплардан җиңел гыйбрәтле риваятьләрне җәмегъ кылдык (тупладык)». Аннары текстның техник ягына аңлатма бирелеп, «Бәгъзе мәчетләр караңгырак вә дәхи бәгъзе имамнар күзгә зәгыйфьрәк буладыр, шул җәһәттән һәркемнең хәленә муафикъ булсын дип, Коръән хәрефе белән бастырмакны мәгъкуль күрдек», — диелә, ягъни биредә сүз Коръәнне нәшер иткәндә кулланыла торган эре хәрефләрдән файдалану турында бара.

Китап кабат Каюм Насыйриның вафатыннан соң китаплар белән сәүдә итүче Исмәгыйль Шәмсетдинов наширлегендә 1904 елда Казан университеты басмаханәсендә дөнья күрә.

Чыг.: Насыйри К. Утыз вәгазь. Казан, 1888.

Әд.: Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфетдин әл-Кустрамави. Габделкаюм ән-Насыйри хәзрәтләре тәрҗемәи хәленә гаид // Шура. 1912. № 8.

Р.Ф.Исламов.

Ф

ФАСИ́ЕВ Камил Фатих улы (10.05.1919, Самара губернасының Бөгелмә өязе (хәзер Татарстанның Лениногорск районы) Тимәш авылы – 02.04.2005, Казан), дәүләт эшлеклесе, философ, философия фәннәре докторы (1972), профессор (1973). ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1979).

ВКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1944), КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (Мәскәү, 1953) тәмамлый. 1939 елдан партия эшендә: 1957–1959 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре, 1959–1960 елларда — ТАССР Югары Советы Президиумы Рәисе, бер үк вакытта РСФСР Югары Советы Президиумы Рәисенең беренче урынбасары вазифаларын башкара. 1961–1963 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры. 1963–1991 елларда Казан университетында, фәнни коммунизм кафедрасы мөдире (1979 елга кадәр). 1959–1963 елларда ТАССР һәм РСФСР Югары Советлары депутаты.

Хезмәтләре иҗтимагый фикер, СССРда милләтара мөнәсәбәтләр, ТАССРда мәдәният, тел үсеше мәсьәләләренә карый. Каюм Насыйри хакындагы мәкаләләрендә галимнең үз халкы тарихына, теленә, гореф-гадәтләренә, рус халкының һәм башка халыкларның мәдәниятләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәтеннән, педагогик эшчәнлеге асылыннан, дөньяга карашларыннан чыгып аның татар иҗтимагый фикере үсешендәге урынын ачыклый, татар халкының социаль һәм мәдәни алгарышка ирешү хокукын яклап чыгуын, рус фәне һәм мәдәнияте казанышларын үзләштерүгә өндәвен ассызыклый, «Каюм Насыйри үзенең барлык милләттәш элгәрләреннән дә катгыйрак рәвештә демократик интернационализм позицияләрендә торды» дип яза, аны «татар халкы демократик иҗтимагый фикеренең атаклы пионеры», «шәркый Россия халыклары мәдәниятләрен рус мәдәнияте белән бәйләүче күпер булдыручы тәүгеләрнең берсе» дип атый.



К.Ф.Фасиев

Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Туганлыкка өндәүче // Социалистик Татарстан. 1975. 13 февраль; Национальное и интернациональное в социалистической культуре. Казань, 1970; На путях пролетарского интернационализма. Казань, 1971; Глашатай дружбы народов // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Иллюзии идеологов антикоммунизма. Казань, 1978.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиографический словарь. Казань, 2004. Т. 3.

И.Х.Хәлиуллин.

ФАСИ́ЕВ Фазыл Салих улы (18.10.1925, Татарстанның Бөгелмә кантоны (хәзер Татарстанның Лениногорск районы) Сугышлы авылы – 2016, Казан), тел галиме, лексикограф, филология фәннәре кандидаты (1962). Бөек Ватан сугышында катнаша.

Казан университетын тәмамлый (1950). 1952–1955 елларда ТАССР Министрлар Советы каршындагы Радиофикация комитетында эшли, Казан фельдшер-акушерлар мәктәбендә татар теле укыта. 1955–1986 елларда — СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында (бүленеп, 1964–1965 елларда — Башкорт университетында) эшли.

Хезмәтләре текстология, лексикология һәм лексикография, тарихи ономастика һәм терминологиягә карый. 4 томлы русча-татарча сүзлек (1955–1959) мөхәррирләренең берсе. «Кыссаи Йосыф» поэмасы җыелма текстының беренче тулы академик басмасын чыгаруга зур өлеш кертә (1983): Татар мәктәпләре, гимназияләре һәм педагогия училищелары өчен татар теле дәреслекләре һәм уку-укыту программалары, шулай ук Каюм Насыйри турында мәкалә авторы. 1976 елда нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Насыйри һәм татар терминологиясе» мәкаләсендә галимнең төрле фәннәр өлкәләрендә хезмәтләр язуын, бер үк вакытта гуманитар фәннәр һәм табигыять фәннәре галиме булуын, үзенә кадәрге дәвердә гасырлар дәвамында татар теленең фәкать гаилә һәм көнкүреш теле булып исәпләнүе һәм андагы терминнар сыйфатында гарәп, фарсы, төрек телләре алынмалары өстенлек итүе белән катгый килешмәвен искәрә, аны М.В.Ломоносов белән чагыштырып, Насыйриның арифметика (хисаплык), геометрия (һәндәсә), табигать фәннәре (табигыять), география (җәгърәфия), ботаника (гыйльме нәбатат), анатомия (гыйльме тәшрих), медицина (гыйльме тыйб), психология (гыйльме рух), педагогика (гыйльме тәрбия, гыйльме тәгълим), грамматика, филология, әдәбият белеме, тарих һәм башка өлкәләр буенча терминнар эшләвен һәм әйләнешкә кертүен югары бәяли. Яңа сүзләр-атамалар булдыруда галимнең дүрт юнәлештә эшләвенә (аффиксларның сүз ясагыч мөмкинлекләрен активлаштыру, мисаллар: бүлгеч, суккыч, сызгыч (такта), кәкрешкә, төшлек, агым, бүлем, ашлама, саналмыш, бүленәсе (сан), укчы, Атлантик диңгез, катулик дине; сүзләр тезмәсеннән җыелма атамалар ясау: инә ташы (магнит рудасы, магнит); катлаулы сүзләрне халык сөйләменнән кертү: башбаштаклык, чынаяк, басмаханә, кунакханә; парлы сүзләр булдыру: кием-салым, ашау-эчү, җиләк-җимеш һ.б.), шул ук вакытта аның алынма терминнарны да куллануны котылгысыз күренеш дип исәпләвенә, ул булдырган терминнарның күбесенең хәзерге вакытта да кулланылышта булуына игътибар юнәлтелә.



Ф.С.Фасиев

Медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар телендә терминология нигезләре. Казан, 1969; Насыри и татарская терминология // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976;

Старотатарская деловая письменность XVIII века. Казань, 1981.

И.Х.Хәлиуллин.

«ФӘВАКИҺЕ́Л-ҖӨЛӘСА́ ФИЛ-ӘДӘБИЯ́Т» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре»), әдәби, лиро-эпик, афористик әсәрләр җыентыгы. Каюм Насыйри тарафыннан язылып, 1884 елда Казан университеты басмаханәсендә нәшер ителә.



К.Насыйри. «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият». Казан, 1884.

Кешенең тормышы, гадәтләре, социаль җитешсезлекләр тәнкыйтьләнгән дидактик характердагы бу иң зур күләмле китабын Каюм Насыйри 1879 елда яза башлый. Кереш өлештә ул үзе файдаланган чыганаклардан 14 йөз гарәп галиме Мөхәммәд ибне Әхмәд әл-Хатыйбның «Катабе Фихрия» һәм Харәзем фикер иясе һәм язучысы Мөхәммәд бине Касыйм бине Ягъкубның (Зәмәхшәри) «Рияз әл-әбрар» дигән хезмәтләрен күрсәтә. Ул кырык бүлектән, ягъни автор үзе билгеләгәнчә, раузадан (бакчадан) гыйбарәт. Мәсәлән, беренче рауза акыл, икенчесе — гыйлем, өченчесе — әдәп турында һ.б. Китапта халык авыз иҗатыннан шактый күп үрнәкләр, әдәби материаллар (хикәяләр, новеллалар, шигырьләр) урын алган. Аларның күпчелеге Көнчыгыш әдәбиятыннан алынса да, татар дөньясына караганнары да байтак. К.Насыйри кереш сүзендә үзен бары тик тәрҗемәче һәм төзүче итеп кенә күрсәтсә дә, асылда үз фикерләрен дә өсти, шәхси карашларын белдерә. Шуңа күрә дә соңгы — кырыгынчы бүлек (рауза) Көнчыгыш әдәбияты традицияләреннән арындырылып, оригиналь эчтәлекле итеп эшләнгән. Анда табышмаклар (27), бәетләр («Чәй бәете», «Уңмаган килен бәете» һ.б.), мәкаль-әйтемнәр (310), фразеологик берәмлекләр, җырлар (116), Габделҗәббар Кандалыйның «Сәхибҗәмал», «Бәдига», «Фәрхи» шигъри әсәрләре урын алган.

«Фәвакиһел-җөләса» белән үз вакытында татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай да таныш булган һәм бу хакта үзенең фикерләрен «Исемдә калганнар» автобиографик повестенда язып калдырган.

Текстның кыскартылган өлеше К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»енә (1953, 1956), «Әсәрләр»енә (1971), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 1 нче томына (1974), тулырагы дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томына (2004) да урнаштырылган.

Л.Н.*Шайдаева* тарафыннан якланган кандидатлык диссертациясендә әлеге хезмәтнең проблематикасы һәм сәнгатьчә үзенчәлекләре карала.

Чыг.: Насыйри К. Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият. Казан, 1884.

Әд.: Гайнуллин М. Каюм Насыйри (Тормышы һәм иҗат юлы) // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары).

Казан, 1948; Шайдаева Л.Н. «Фаваких аль-джуласа» Каюма Насыри: прблематика и художественные особенности: Автреф. дис. ... канд. филол. наук. Казан, 2010.

Р.Ф.Исламов.

ФӘЙЗОВА Фирая Сафа кызы (29.07.1955, Татарстанның Арча районы Олы Әтнә авылы), педагог. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2016).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, 1976–1978 елларда Казанның Е.Г.Ласточкина исемендәге сәламәтлеге чикләнгән балалар интернат-мәктәбендә тәрбияче, 1978–1984 елларда — Биектау районы Биектау авылы 2 нче урта белем бирү мәктәбендә, 1984–1988 елларда — Казан шәһәре 101 нче урта белем бирү мәктәбендә озайтылган көн төркеме тәрбиячесе, 1988–1990 елларда Казандагы 58 нче, 1990–2018 елларда — 141 нче урта белем бирү мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, милли мәсьәләләр буенча директор урынбасары булып эшли.

Хезмәтләре балаларны татар теленә өйрәтү мәсьәләләренә, дәреслекләр, уку-укыту программалары, методик кулланмалар төзүгә карый. Ул хезмәтләрендә татар милли мәдәнияте үзенчәлекләренә нисбәтле гореф-гадәтләр, йолалар, милли бәйрәмнәр турындагы материалларга таяна. Р.Р.Нигъмәтуллина белән берлектә 5 нче, 6 нчы, 8 нче сыйныфлар өчен «Татарча да яхшы бел» уку-укыту–методик комплект (дәреслек, методик ярдәмлек, аудиодиск, эш дәфтәре, укучыларның белемнәрен тикшерү дәфтәре) эшли.

Татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадасы җиңүчесе әзерләгәне өчен ТР Мәгариф министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә (1999). РФнең иң яхшы укытучылары «2009 — Бөтенроссия туган тел һәм шулай ук рус теле укытучыларының осталык дәресе» (3 нче урын), ТРның иң яхшы укытучылары «Мәгариф» приоритетлы милли проекты (2012) конкурслары җиңүчесе.



Ф.С.Фәизова

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, РФнең Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар теле (Татарча да яхшы бел: Экспериментальный учебник для 5 класса средней общеобразовательной школы с русским языком обучения (для русскоязычных учащихся): в 2 частях. Казан, 2005 (автордаш); Татар теле (Татарча да яхшы бел: Экспериментальный учебник для 6 класса средней общеобразовательной школы с русским языком обучения (для русскоязычных учащихся). Казан, 2006; Татар теле (Татарча да яхшы бел: Учебник для 8 класса средней общеобразовательной школы с русским языком обучения (для русскоязычных учащихся). Казан, 2009 (автордаш).

Ф.Г.Камальтдинова.

ФӘТХУ́ЛЛОВА Кадрия Сөнгат кызы (18.10.1959, Татарстанның Актаныш районы Актаныш авылы), педагог, педагогика фәннәре кандидаты (2002). РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2015), ТРның атказанган укытучысы (2022), ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2012).

Казан педагогия институтының чит телләр факультетын тәмамлаганнан соң (1982), 1989 елга кадәр Казан шә-

һәренең 78 нче мәктәбендә француз теле, 1992–1994 елларда — 132 нче мәктәбендә татар теле укыта. 1994–1996 елларда РФ Мәгариф министрлыгы Милли мәгариф проблемалары институтының Татарстан филиалында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1996 елдан Казан университетында (2010 елдан Казан федераль университеты) чит телле аудиториядә татар теле укыту кафедрасы укытучысы, доцент. Ул шулай ук университет каршында эшләп килүче «Ана теле» татар онлайн-мәктәбе җитәкчесе.



К.С.Фәтхуллова

Хезмәтләре рус телле укучыларга татар телен укыту методикасына һәм лексикографиясенә карый. «Татар диалоглы һәм монологлы сөйләменә өйрәтү системасы» (2002) китабында рус телле укучыларда татарча сөйләм телен үстерүнең лингвометодик, психологик-дидактик проблемалары ачыла, рус мәктәпләрендә татар теле укытуның торышы анализлана, сөйләшергә өйрәтү өчен әзерлек һәм коммуникатив күнегүләр, шулай ук татар телен чит тел буларак укыту методикасы тәкъдим ителә.

«Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагы оешмасы, ТР Профсоюзлар федерациясе тарафыннан ТР Рәисе ярдәмендә уздырыла торган «Ел хатын-кызы» бәйгесенең «Хатын-кыз галимә» номинациясендә 2014 елгы лауреаты була.

Хезм.: Рус телле укучылар өчен дәреслек. Казан, 2002 (автордаш); Татар теле. 9 сыйныф. Татарча сөйләшик. Казан, 2022 (автордаш); Система обучения татарской диалогической и монологической речи. Казань, 2002; Татарско-русский, русско-татарский краткий словарь. Казань, 2023 (автордаш).

Ф.С.Гыйниятуллина.

ФӘХРЕТДИ́Н (Фәхретдинов) Ризаэтдин (Риза) (04.01.1859, Самара губернасының Бөгелмә өязе (хәзер Татарстанның Әлмәт районы) Кичүчат авылы – 12.04.1936, Башкортстанның Уфа шәһәре), дин эшлеклесе, мәгърифәтче галим, тарихчы, язучы, журналист, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе (мөфти).


Бөгелмә өязе Түбән Шәлчәле (рәсми атамасы Түбән Чыршылы) (1865–1867, 1869–1889), Казан губернасының Чистай шәһәре (1867–1868) мәдрәсәләрендә белем ала. Уфада Диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, имам-хатип һәм мөдәррис дәрәҗәсенә шәһадәтнамә алганнан соң, 1889–1890 елларда Илбәк авылы мәчетендә имам булып тора. 1891 елдан Уфа шәһәрендә — 1891–1905 елларда Диния нәзарәтендә казый вазифаларын башкара, 1891 елда аңа ахун дәрәҗәсе бирелә. Р.Фәхретдин төп эшеннән буш вакытларында нәзарәтнең архивын тәртипкә китерә, Россия мөселманнары турында төрле тарихи материалларны, метрика дәфтәрләрен туплый.

Алтын приисклары хуҗалары, танылган иганәчеләр һәм җәмәгать эшлеклеләре бертуган Мөхәммәтшакир (1857–1912) һәм Мөхәммәтзакир (Дәрдемәнд, 1859–1921) Рәмиевләр Оренбург шәһәрендә «Вакыт» газетасы нәшер итә башлагач, аларның чакыруы буенча шунда күченеп, газетаның мөхәррире булып эшли башлый. Озакламый «Шура» журналының (1908–1918) баш мөхәррире була. Басмада иҗтимагый тормыш (гомуми хезмәтләр, иҗтимагый хроника һәм газета-журналларга күзәтү, милли, хатын-кыз һәм хокук мәсьәләләре, дин

һәм дин галимнәре, фән һәм хорафат, миссионерлык хәрәкәте), тарих (төрле илләр, төрки халыклар тарихы), татар тарихы мәсьәләләре, философия, икътисад, мәгариф, әдәбият (фольклор, әдәбият белеме, шигърият, проза), тел белеме, сәнгать, медицина, сәламәтлек һәм гигиена, табигыять фәннәре (география, астрономия, биология), техника һәм фән яңалыклары, статистик мәгълүматлар һәм башка проблемалар яктыртыла. Бер үк вакытта ул «Хөсәения» мәдрәсәсендә шәкертләр укыта. 1918 елдан янә Уфага күченеп, Диния нәзарәтенә казыйлык хезмәтенә тәгаенләнә. Мөфти Галимҗан Баруди (1857–1921) вафат булгач, вакытлыча мөфти вазифасын башкара. 1922 елда Р.Фәхретдинне мөфти итеп сайлыйлар һәм 1923 елда ул рәсми рәвештә раслана. Шул елда Диния нәзарәте аның башлангычы белән «Ислам мәҗәлләсе» («Ислам җыентыгы») журналын нәшер итә башлый.

Нәзарәттә вакытлыча сакланган «Госман Коръәне»н Ташкентка илтеп рәсми тапшыруда хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән комиссиянең җитәкчесе була (1923). СССР Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилеенда чакырылган мактаулы кунак сыйфатында катнаша (1925). Анда академиклар И.Ю.Крачковский, А.Н.Самойлович һәм башка галимнәр белән якыннан аралаша, алар белән дустанә мөнәсәбәтләр алга таба да дәвам иттерелә. Мәккә шәһәрендә уздырылган Бөтендөнья мөселманнарының беренче конгрессында (1926) СССР делегациясенең җитәкчесе була, конгрессның вице-президенты итеп сайлана.

Октябрь революциясенә (1917) кадәр Р.Фәхретдинның алтмыштан артык китабы дөнья күрә, кайберләре дистәдән артык тапкыр кабатлап бастырыла. Аерым алганда, алар арасында: укыту һәм дин мәсьәләләре турында «Әт-төхфәт әл-әнисия» («Дусларга бүләк») һәм «Китаб әл-игътибар» («Ышаныч китабы») (1887–1888), «Коръән вә табәкат» (1900), «Җәвамигъ әл-кәлам шәрехе» («Гыйбарәләр җыелмасына шәрехләр», 1911, 1917); күренекле шәхесләр һәм дин эшлеклеләренә багышланган «Асар» («Эзләр», 1–2 т., 1900–1908; 1–4 т., 2006–2010); танылган Шәрекъ галимнәренең эшчәнлеген яктырткан («Мәшһүр ирләр» сериясендә) Ибне Рөшд (1905), әл-Мәгари (1908), әл-Газали (1910), Ибне Таймия (1911), Ибне Фазлан (1915), Ибне Баттута (1917), «Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле» (1917); күренекле мөселман хатын-кызлары хакында «Мәшһүр хатыннар» (1905); тәрбия мәсьәләләренә караган «Тәрбияле ана» (1898), «Тәрбияле ата» (1898), «Тәрбияле бала» (1898), «Шәкертлек адәбе» (1899), «Тәрбияле хатын» (1899), «Гаилә» (1902); танылган иганәчеләр турында «Әхмәд бай» (1910) һәм башка хезмәтләре киң таныла. Язучы буларак аның «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) һәм «Әсма, яхуд Гамәл вә җәза» (1903) повестьларында Европа белеме алган мөселман хатын-кыз идеалы тасвирлана. Көндәлек матбугатта җиде йөзләп мәкаләсе дөнья күрә.



Р.Фәхретдин

Р.Фәхретдин «Шура» журналының 1912 елгы 21 нче санында «Габделкаюм Насыйри» дигән мәкалә урнаштыра. Анда, аерым алганда, ул: «Габделкаюм әфәнденең яшьлегендә, хәтта егетлек вакытларына иреште гендә улан хәлләре хакында мәгълүматы-

мыз юк, соңгы хәлләре хакында хәбәремез аз. Буның гасырына йитештек вә буның сәламәт вакытында бер дәфга (бер тапкыр) Казан шәһәренә вардык исә дә күрешә алмадык», — дип яза. Аның хезмәтләрен нәшер итәргә тырышуы сәбәпле рәхмәт әйтеп язган бер хаты сакланган булуы, әмма тентү вакытында алынып, кире кайтарылмавына үкенеч белдерә. Язмада шулай ук Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче Сөләйман *Аитов* сөйләгән сүзләрне китереп, К.Насыйриның аның өендә түләүсез яшәп, улы һәм Троицкидан Габделвәли Яушевның улы янына тагын алты фәкыйрь баланы кушып укытуы турында мәгълүмат бирә.

Станислав лентасындагы «Тырышлык өчен» көмеш һәм алтын медальләре белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сәлимә, яки Гыйффәт. Казан, 1898; Адәбе тәгълим. Оренбург, 1902; Тәрбияле хатын. Оренбург, 1902; Мәшһүр хатыннар. Оренбург, 1903; Шәкертлек адәбе. Казан, 1903; Әсма, яки Гамәл вә җәза. Оренбург, 1903; Әбу әл-Галәә әл-Мәгарри. Оренбург, 1908; Әхмәд бай. Оренбург, 1910; Ибне Баттутаның Дәште Кыпчакта сәяхәте. Оренбург, 1917; Җәвамигыль-кәлим. Оренбург, 1917; Шәех Зәйнулла хәзрәтнең тәрҗемәи хәле. Оренбург, 1917.

Әд.: Даутов Г.Ф. Риза Фәхретдинов: галим һәм әдип. Казан, 2006; Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: Науч.-биогр. сборник / төз.: Р.Мәрданов. Р.Миңнуллин, С.Рәхимов. Казан, 1999; Баишев Ф.Н. Общественно-политические и нравственно-этические взгляды Ризы Фахретдинова. Уфа, 1996; Байбулатова Л. Ризаэтдин Фахретдин. Казань, 2021; Battal-Taymas A. Kazanlı Türk Meşhurlarından Rizaeddin Fahreddinoğlu. Kişiligi. Fikir hayatı ve Eserleri ve iki ilâve. İstanbul, 1958; Türkoğlu İ. Rusya Türkleri Arasındaki Yenileşme Hareketinin Öncülerinden Rizaeddin Fahreddin (1858–1936) / İ. Türkoğlu. — İstanbul: Ötüken, 2000.

Р.Ф.Исламов.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Равил Габдрахман улы (14.03.1937, Татарстанның Балтач районы Кариле авылы – 10.03.2014, Казан), археолог, тарихчы, тарих фәннәре докторы (1990), ТР-ның атказанган фән эшлеклесе (1997). Язучылар берлеге әгъзасы (2003). ТР Дәүләт бүләге (1994), Һади Атласи исемендәге бүләк (1996) лауреаты.

Казан педагогия институтын тәмамлый (1963). 1966 елдан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1997 елдан ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында (1992 елдан — әйдәп баручы фәнни хезмәткәр) археология бүлегендә эшли. Бер үк вакытта «Татарская археология» журналының баш мөхәррире (1997–2006).

Татар археология экспедициясе отряды белән җитәкчелек итә; экспедиция 1959–1972 елларда, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урданың Болгар олысы һәм Казан ханлыгы археология истәлекләре җыелмасын (картасын) төзү максаты белән, Татарстан, Ульяновск, Самара өлкәләре һәм Чуваш АССР территорияләрен археологик яктан тоташ тикшереп чыга, 1200 дән артык истәлек ачыклана һәм тикшерелә. 1970–2000 елларда Камай шәһәрлегендә, Рус Урматы авыллыгында, Биләр шәһәрлегендә казу эшләре белән җитәкчелек итә, Болгар, Царёв һәм Селитренное шәһәрлекләрендә һәм башка урыннарда алып барылган археологик тикшеренүләрдә катнаша. Биектау районында Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгын оештыручыларның берсе.

Хезмәтләре Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихына һәм археологиясенә карый.

6 томлык «Татарстан Республикасының археологик картасы» (1981–1990), «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» (1996, 2001) уку әсбабы, Каюм Насыйри һәм башкалар турында мәкаләләр авторы. 1976 елда нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Каюм Насыйриның Казан татарларының тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә кертkән өлеше» мәкаләсендә галимнең тарихчы белгечлегенә, археологик тикшеренүләр методикасына ия булмавына карамастан, башлыча халык авыз иҗаты әсәрләрен, тарих-эпиграфика мәгълүматларын, этнография, археология материалларын теркәү һәм аларны аңлату-бәянлау юлы белән Казан татарларының борынгы тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә өлеш кертүе тикшеренүчеләрнең кырда алып барган фәнни эзләнүләрне җирле халыктан сораштырулар белән бергә үреп алып барган алдагы буыны — археологлар һәм эпиграфика белгечләренең эшчәнлеге өчен үрнәк булуын, аның Казан ханлыгы чоры эпиграфика истәлекләрен беренче булып өйрәнүче икәнлеген, Казан тарихы буенча материаллар җыюын һәм бастырып дөньяга чыгаруының зур әһәмиятен ассызыклый. Ул К.Насыйриның «Аксак Каратун, Пугачёв һәм Ишбулат мулла хакында» хезмәтенең татар халкының Казан архиепископбына, пугачёвчылар хәрәкәтенә карата мөнәсәбәтен чагылдырган күп кенә фактларга бай булуы, «Зөбдәт мин тәварихи әр-Русь» («Россиянең кыскача тарихы», 1890) китабын Россия тарихын популярлаштыру, киң даирә татар укучыларын аның белән таныштыру җәһәтендә югары бәяли.



Р.Г.Фәхретдинов

Медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Ташлар моңы. Казан, 1978; «Мондадыр безнең бабайлар». Казан, 1992; Кичке азан. Казан, 1997; Татар тарихы (кыскача басма). Казан, 1999; Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория, Казань, 1973; Вклад Каюма Насыри в исследование истории и археологии казанских татар // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

И.Х.Хәлиуллин.

ФОЛЬКЛО́Р (инглиз теленнән folklore — «халык зирәклеге»), халык тарафыннан телдән иҗат ителеп, күп еллар, хәтта гасырлар буе халык хәтерендә сакланып килгән сүз, музыка, сынлы сәнгать һәм башка сәнгать төрләре әсәрләре җыелмасы. Башлыча өч төркемгә бүленә: халык авыз иҗаты (халыкның поэтик иҗаты), музыкаль иҗаты, халык биюләре. Терминны фәнгә 1846 елда инглиз галиме Уильям Томсон кертә, татар филологиясендә аны тәүге тапкыр 1926 елда Гали *Рәхим* куллана. 1950 еллар уртасыннан фәндә «фольклор» термины белән бергә «татар халык иҗаты» төшенчәсе дә киң тарала.

Сүз фольклоры эпос һәм лирикага бүленә. Эпоска архаик-героик һәм мәхәббәт-лирик тематикалы дастаннар керә. Татар фольклорының шактый өлешен халык лирикасы тәшкил итә. Хуҗалык эшләре, календарь һәм гаилә тормышы белән бәйле йолалар вакытында йола җырлары, туй җырлары башкарыла. 1920–1930 елларда уен җырлары формалаша, 1950 елларга кадәр кулланышта булалар. Татар проза фольклорында әдәби һәм тарихи-эстетик кыйммәте ягыннан әһәмиятле

урыннарның берсен *әкиятләр* алып тора. Лиро-эпик жанрның үзенчәлекле төре — тарихи җырлар. Аларның эчтәлеге сугышларга, социаль һәм милли җәберләүләргә, төрле катлау кешеләренең тормыш-көнкүреш хәлләренә, аерым шәхесләрнең язмышларына бәйле. Охшаш тематика кайбер лиро-эпик жанрларга хас: *риваятьләр* – реаль фактларга һәм вакыйгаларга еш кына хыялый уйдырмалар өстәп, аларны дөреслеккә охшатып, телдән сөйләнә торган хикәяләр; легендалар – дөреслеккә дәгъва итүче фантастик характердагы хикәяләр; бәетләрдә эмоциональ яктан бай итеп фаҗигале язмышлар, дөнья, яшәү һәм үлем турында лирик уйланулар бәян ителә; мөнәҗәтләрнең асылында Аллаһы Тәгаләгә һәм аның пәйгамбәрләренә мөрәҗәгать итү, ялварып ярлыкауны сорау ята. Татар фольклорында афористик жанрлар системасы формалаша: *мәкальләр*, әйтемнәр, *табышмаклар*, тизәйткечләр, *санамышлар*, им-томнар һ.б.

Фольклорны туплау, теркәү, бастыру, тикшерү, тасвирлау һәм классификацияләү белән фольклористика фәне шөгыльләнә. Аңа, фән буларак, Каюм Насыйри нигез сала. Тарихта беренчеләрдән булып, ул татар фольклорына караган материалларны туплый, тикшерә һәм бастыра башлый, татар халык авыз иҗаты әсәрләрен системага салу омтылышы ясый. Аерым алганда, Казан губернасы Зөя өязенең Айдар, Бакырчы, Бәчек, Борнаш, Борындык, Кормаш, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Мулла Иле, Норлат, Югары Шырдан (*Кече Шырдан*), Цивильск өязенең Шигали авылларында булып, җирле халыктан сораштырып халык авыз иҗаты әсәрләрен (әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, *җырлар*, *бәетләр*, санамышлар) җыйнап туплый, аларны «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» «*Император Рус географ ия җәмгыяте язмалары*» (1880. Т. VI), «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)» «*Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*» (1896. Т. XIII, чыг. 5), П.А.*Поляков* белән автордашлыкта «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» (1900, Т. XVI, 2 чыг.) хезмәтләрендә бастыра. «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» хезмәтенә багышлаган кереш мәкаләсендә Петербург профессоры В.В.*Григорьев*: «Казан университетында алган Европа белеме аны акыл мөнәсәбәтендә шундый югарылыкка күтәргән — ул исламга объектив карый торган безнең мөселманнардан беренчесе... Аның фәнгә тартым тикшеренүләренең мөселманлык мәгънәсендә пропаганда характерын алу ихтималыннан куркырга бернинди дә сәбәп юк», — дип яза. Өч өлештән торган («Ышанулар», «Сынамышлар», «Мәҗүси йолалар һәм әфсен-өшкерүләр») әлеге хезмәттә татарларның мәҗүсилектән калган йолалары, хорафатлары, галимнең үзе тарафыннан тупланган татар халык әкиятләрендәге уйдырма затлар (су бабасы, су иясе, су анасы, юха, убыр, албасты, өрәк, бичура, өй иясе, абзар иясе, чәчәк анасы, чәчәк иясе, шүрәле, җен, дию пәрие) тасвирлана, әфсен-өшкерүләрдән мисаллар китерелә.

«Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)» мәкаләсендә автор татар халык авыз иҗаты әсәрләренең 417 үрнәге (28 табышмак, 244 мәкаль, 145 җыр) белән таныштыра, җырларны 7 төргә — моңсу җырлар (13 җыр), мактау җырлары (12), кавышу теләгән белдергән җырлар (26), кайгылы җырлар (14), үкенүле җырлар (15), аерылышу җырлары (36),

мәхәббәт җырлары (29) төрләренә бүлеп карый. 315 мәкаль һәм әйтем, 117 җыр, 27 табышмак, 3 бәет К.Насыйриның «*Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият*», 150 гә якын мәкаль, әйтем һәм табышмак, күп кенә җырлар һәм такмаклар «*Ләһҗәи татари*» хезмәтләренә кертелә. Казан профессоры Н.Ф.*Катанов* әлеге әсәргә карата язган кереш өлешендә: «Насыйров әфәнде Казан татарлары халык иҗаты ядкәрләрен үзеннән элгәре җыючыларга караганда беренче мәртәбә шундый күп мәкальләр һәм җырлар тәкъдим итте. Насыйров әфәнде тәкъдим иткән материаллары белән үзе гомер буе алар арасында яшәгән халкының көнкүреше һәм телен яхшы белүен тулысы белән дәлилли», — дип билгеләп уза.

А.Р.*Еникиева* фикеренчә, мәгърифәтче галим халык иҗаты әсәрләренең эстетик кыйммәтен иң саф һәм нечкә кешелек хисләренең гәүдәләнешендә күреп, фольклорны халык мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүдә хаклы рәвештә җитди чыганак буларак бәяләгән. «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» язмасында К.Насыйри тарафыннан Казан губернасы авылларында язып алынган 11 татар әкияте урнаштырылган, алар кириллица имлясында Николай Катанов тарафыннан транскрипцияләнгән, П.А.Поляков рус теленә тәрҗемә итеп, башлыча рус, удмурт, шулай ук исемнәре күрсәтелмәгән кыргыз халык әкиятләре белән чагыштырылган. Татар халык әкиятләре басылу уңае белән «Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» редакциясе тарафыннан түбәндәге аңлатма бирелә: «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең хакыйкый әгъзасы, танылган мөселман галиме Габделкаюм Насыйров тарафыннан гарәп-татар транскрипциясе нигезендә Казан губернасында язылган татар әкиятләре (барлык саны — 11) укучылар игътибарына тәкъдим ителә. Аның Казан татарлары әкиятләре тюркология белән шөгыльләнүче Көнбатыш Европа галимнәре өчен тел ягыннан кызыклы булыр дигән уйдан чыгып, әлеге фәнни җәмгыятьнең хакыйкый әгъзасы Н.Ф.Катанов, К.Насыйровның үз җитәкчелеге астында, барлык әкиятләрне фән дөньясында гомуми кабул ителгән һәм академик транскрипция дип аталып йөртелгән төгәл транскрипциягә халык телендә сөйләнгәнчә салып чыкты... Әкиятләрнең татар теленә шактый якын итеп эшләнгән русча тәрҗемәсе һәм әкиятләрнең башка халыклар (Идел буе, Кавказ һәм Азия халыклары) әкиятләренә булган охшашлыкларын чагыштыру П.А.Поляков тарафыннан эшләнде; бу әкиятләрдә, я үзләренең гомуми төп фикерләре, яки аерым күренешләре яки кайберләре белән тулысынча охшашлык бар».

Татар фольклористикасы үсешенә ул чорда шәркыятьче галим-тюрколог В.В.*Радлов* зур өлеш кертә. 19 йөз башында Казанда 87 фольклор җыентыгы нәшер ителә. Шулай ук К.Насыйриның фольклор өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге Габдулла *Тукай*, Фатих *Әмирхан*, Гали *Рәхим* һәм башкаларга халык авыз иҗатын өйрәнгәндә үрнәк һәм чыганак була.

Әд.: Мәхмүтов Х. Алтын бөртекләр (Каюм Насыйри сүзлекләрендә фольклор әсәрләре) // Казан утлары. 1972. № 3; шул ук. Энциклопедист галим // Татарстан яшьләре, 1975. 11 февраль; шул ук. Халык иҗатына мәхәббәт // Социалистик Татарстан. 1975. 13 февраль; Миңнуллин К. Һәр чорның үз җыры. Казан, 2003; Ярми Х. Татар фольклорын туплау һәм өйрәнү тарихы // Татар халкының

поэтик иҗаты. Казан, 1967; Махмутов Х. Место Каюма Насыри в истории татарской фольклористики // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; шул ук. Афористические жанры татарского фольклора. Казань, 1995; Насыров А.К. Образцы народной литературы казанских татар (загадки, пословицы, песни) // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1896. Т.XIII, вып. 5; Насыров А.К., Поляков П.А. Сказки казанских татар в сопоставлении их со сказками других народов // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. 1900. Т.XVI, вып.2; Насыров К. Поверья и обряды казанских татар // Записки императорского Русского географического общества. 1880. Т. VI.

И.Х.Хәлиуллин.

Х


ХА́КОВ Вахит Хөҗҗәт улы (16.08.1926, Татарстанның Буа кантоны (хәзер Буа районы) Күзби авылы – 20.06.2008, Казан; туган авылында җирләнә), тел галиме, тюрколог, филология фәннәре докторы (1972), профессор (1974). ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1987), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Бөек Ватан сугышында катнаша.

Казан университетын тәмамлый (1957). 1949 елдан Буа районы мәктәпләрендә укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1960 елдан Казан университетында, татар теле кафедрасы мөдире (1989–1994); бер үк вакытта, 1996–2008 елларда, ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институтында эшли. Татарстан радиосында «Тел күрке — сүз» тапшыруын оештыра һәм 30 ел дәвамында аны әзерләүдә катнашып килә.

Хезмәтләре татар әдәби теле стилистикасына, сөйләм культурасына, текстологиягә һәм мәктәптә матур әдәбият телен өйрәнү методикасына карый. «Татар әдәби теле диахрон һәм синхрон аспектларда» хезмәте татар әдәби теле тарихын чорларга бүлү мәсьәләләренә багышлана, әдәби телнең традицияләре яктыртыла, сөйләм һәм язма формалары тасвирлана. Ул шулай ук югары уку йортлары һәм урта мәктәпләр өчен татар теле дәреслекләре авторы.

Каюм Насыйри иҗатына багышланган хезмәтләрендә, аеруча 1976 елда нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Татар тел белемендә К.Насыйри традицияләре» мәкаләсендә, шулай ук «Тел — тарих көзгесе» китабының аңа багышланган өлешендә тел белеменең мәгърифәтче галим хезмәтләре тәэсирен кичергән аннан соңгы дәвере тарихын өч чорга (19 йөз ахырыннан 1917 елга кадәр, 20 йөзнең 20–30 еллары, 40–70 еллар) бүлеп тикшерергә, К.Насыйриның тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеген ике юнәлештә — милли телнең фәнни-теоретик мәсьәләләрен тикшерү һәм әдәби тел нормаларын лексик, фонетик, грамматик яктан төрле аспектта гамәли юнәлештә үстерү һәм эшкәртү юнәлешләрендә карарга тәкъдим итә; галимнең фәнни һәм фәнни-популяр әсәрләрендәге аеруча ачык чагылган түбәндәге стиль үзенчәлекләрен аерып күрсәтә: 1) сөйләм бер зат исеменнән әйтелгәндә дә күплек формасын куллану, 2) «сез» алмашлыгын мөрәҗәгать өчен түгел, бәлки хикәяләү алымы өчен алу, 3) әчтәлекне көчәйтү һәм фикерне тагын да ышандырырлык итеп күрсәтү өчен чагыштырулардан һәм башка сурәтләү алымнарыннан файдалану, 4) сорау һәм җавап алымын киң кулланышка кертү, 5) фәнни сөйләмдә фикерне ачыклап һәм төшендереп бирү ягыннан «ягъни» сүзенең функциясен киңәйтү. К.Насыйриның әлеге фән үсешенә керткән өлешен, аерым алганда,

аның «Әнмүзәҗ» әсәрен (В.Хаков аны «татар теленең XIX йөздәге иң яхшы грамматикасы» дип атый) һәм тәүге «Ләһҗәи татари» аңлатмалы сүзлеген югары бәяли, аларның алдагы чорларда яңа грамматикалар һәм сүзлекләр барлыкка килүгә этәргеч бирүен ассызыклый, галим традицияләренең алдагы буын белгечләр тарафыннан дәвам иттерелүен билгеләп уза.



В.Х.Хаков

2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар стилистикасына кереш. Казан, 1963; Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан, 1972; Традицияләр дәвамы (Каюм Насыйриның тууына — 150 ел) // Социалистик Татарстан. 1975. 14 февраль; Стилистика һәм сүз сәнгате. Казан, 1979; Татар әдәби теле тарихы. Казан, 1993; Хәзерге татар әдәби теле: Стилистика. Казан, 1999; Тел — тарих көзгесе. Казан, 2003; Традиции К.Насыри в татарском языкознании // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Әд.: Фәйзуллин Р. Тел сагында тора солдат // Казан утлары. 2006. № 8; Хаков укулары — 2011: Хаков истәлегенә багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан, 2011; Казанская лингвистическая школа. Казань, 2008.

И.Х.Хәлиуллин.

ХАЛИ́КОВ Фиринат Гаптухай улы (28.08.1957, Украина ССРның Донецк шәһәре), рәссам, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Россия Сәнгать Академиясе мөхбир әгъзасы (2012), СССР Рәссамнар берлеге (1989) әгъзасы.



Ф.Г.Халиков

Киров сәнгать училищесын (1984), Х.Г.Якупов җитәкчелегендә Россия Сәнгать академиясенең нәкышь иҗат остаханәсен (1996) тәмамлый. Россия Сәнгать академиясенең Казандагы Иҗат остаханәләре җитәкчесе (2014 елдан). Академик реализм традицияләрендә эшләүче, тарихи жанр остасы, әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Баштагы чорда пейзажга мөрәҗәгать итә: «Үлеп баручы авыл» картиналар сериясен яза (1982–1993). 1992 елда Казанга күченеп килгәч, иҗатында төбәкнең урта гасырларга караган тарихын сәнгатьтә чагылдыруга багышланган яңа этап башлана. Ул археолог А.Х.Халиковның фәнни хезмәтләрен бизәү өчен Болгар һәм Алабуга шәһәрләре тарихына багышланган график эшләр (акварель, гуашь) циклы: «Алмыш хан», «Болгардагы Кара пулат», «Төньяк мавзолей», «Иерусалим ермагы» (барысы да — 1993); «Шайтан каласы» (1994) иҗат итә.

1994 елдан Ф.Халиков Казан ханлыгының сәнгатьчә елъязмасын булдыру максатын куеп, масштаблы тарихи һәм тематик жанрда күп фигуралы картиналар һәм архитектур пейзажлар иҗат итү өчен әдәбият, археология, сәнгать һ.б. буенча мәгълүмат туплый. Алар барысы да Казанның барлыкка килүеннән башлап, 16 йөз уртасында җимерелүенә кадәрге тарихын сурәтләүгә багышлана: «16 йөздә Арча кырыннан Казан күренеше», «Болак ягыннан кышкы Казан күренеше», «Ханның чыгуы» (барысы да — 1996);

«16 йөздә Казан күренеше», «Борынгы Кремль» (икесе дә — 2000), «Иртә язда Казан Кремленең эчке ягы», «1552 елгы октябрь вакыйгалары», «Казанны саклаучыларга багышлана. Реквием» (барысы да — 2001).

Ф.Халиков эшләренең бер өлеше 16 картиналы «Мәңгелек Казан» сериясенә берләштерелә. Аңа, киң панорамалы һәм күп сюжетлы күренешләр белән бергә, тарихи шәхесләр белән бәйле вакыйгаларга багышланган картиналар да керә: «Сөембикәнең хушлашуы», «Шаһгали һәм Иван Грозный Казан янында», «Олуг Мөхәммәт», «Ядегәр ханның бирелүе» (барысы да — 1998), «Сөембикә һәм Үтәмеш» (2007) һ.б.

Казан, Болгар күренешләре белән пейзажлары арасында «Кызыл йорт», «Мәржани мәчете», «Алтын кич» (барысы да — 1994), «Казандагы ишегалды» (1995), «Болгар иртәсе», «Болгарда Көнчыгыш төрбә» (икесе дә — 2003), «Шырдан панорамасы» (2002) һ.б. бар.



Ф.Г.Халиков. «Шырдан панорамасы». Киндер, майлы буяу. 2002.

Ф.Халиковның «Шырдан панорамасы» картинасында Каюм Насыйриның туган авылы *Кече Шырдан* күренеше сурәтләнгән. Әсәр 20 йөз башында төшерелгән фоторәсем нигезендә язылган. Йортларның, хуҗалык корылмаларының урнашуы шул чорга хас. Рәссамның күпчелек тарихи пейзажларындагы кебек монда да табигатьтә көз төсмерләре өстенлек ала башлаган урак өсте вакыты сурәтләнгән. Алгы планда хатын-кызларның уректан бушаган вакытлары, ашлык сосланнары тасвирланган, ерактарак көтү күренә. Автор табигатьнең матурлыгын шул чор авыл күренеше һәм крестьян хезмәте белән бер яссылыкта ача. Картина ТР Милли музее филиалы — Каюм Насыйри музеенда (Казан) саклана.

Рәссам портретлары: «Җилпәзә белән портрет» (1993), «Света верандада», «Люда. Милли кием «Сүрәкә» (барысы да — 1994), «Каюм Насыйри» (2005) һ.б. Портрет жанрында иҗат ителгән «Каюм Насыйри» картинасы рәссам Зөфәр *Гыймаевның* «Каюм Насыйри» картинасына (2001) охшатып ясалган. Шул ук үткен, зирәк, аз гына борчулы, аз гына үпкәле караш. Башында кырпулы бүрек, өстендә затлы мех якалы камзул. Кулында «Әнмүзәҗ» грамматика китабы. *Каюм Насыйри музеенда* саклана.

Бөтенроссия — «Ватанны саклаучыларга» (Мәскәү, 1990), «Борынгы Казан» (Казан, 1999); «Ислам кабул ителүнең 1400 еллыгы» (Мәскәү, 2000), Казанның 1000 еллыгына (Мәскәү, 2005), Познань шәһәрендә (Польша) халыкара күргәзмә-ярминкәдә, Вюнсдорф (ГДР) шәһәрендә совет сәнгате күргәзмәсендә (икесе дә — 1989) күргәзмәләрендә катнаша. Мәскәү, Будапешт, Пиза, Истанбул, Хельсинки, Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында һәм башкаларда узган 70 тән артык күргәзмә проектларының авторы һәм катнашучысы.

Картиналары Рус музеенда (Санкт-Петербург), Тарих музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казан музейлар комплексы фондында, ТР Милли музеенда, Ма-

ри республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Киров шәһәре Бертуган Васнецовлар исемендәге сәнгать музеенда һ.б. саклана.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», Россия сәнгать академиясенең көмеш һәм алтын, Россия Мөфтиләр Шурасының «Рухи бердәмлек өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнә.

Әд.: Мамаева Т. Сказания о земле Казанской: Островки любви и надежды художника Фирината Халикова // Казань. 1998. № 2; Ситдиков А. Столица ханства: Древняя Казань // Родина. 2005. № 8. Шагеева Р., Магдеев Р. Фиринат Халиков. М., 2017.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХАЛИ́Т (Халитов) Гали Мөхәммәтгали улы (26.06.1915, Казан губернасы Тәтеш өязе (хәзер Татарстанның Тәтеш районы) Үтәмеш авылы – 24.8.1992, Казан), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1968), ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1975, 1981).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1936), Арча педагогия училищесында укыта. 1942 елдан ТАССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1945 елдан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты) эшли. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ иҗатларын; 20 йөз башы татар әдәбиятын, иҗтимагый-сәяси һәм милли-азатлык хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә аның идея-эстетик үзенчәлеген; иҗади алымнарның (мәгърифәтчел һәм тәнкыйди реализм, романтизм, романтик реализм) эволюциясен өйрәнә.

Хезмәтләре 20 йөз башы һәм 1920–1930 еллар татар поэзиясе тарихына карый.



Г.М.Халит



Я.И.Ханбиков

«Кызыл Татарстан» газетасында (1945) Каюм Насыйриның тууына 120 ел тууга багышланган «Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе һәм галиме» мәкаләсендә әдипнең тормыш юлы, эшчәнлеге бәян ителә, татарларда фән үсешенә, мәгърифәтчелек таралышына, аларны рус мәдәнияте белән таныштыруга, татар әдәби теле формалашуга керткән өлеше югары бәяләнә.

Хезм.: Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе һәм галиме // Кызыл Татарстан. 1945. 21 февраль; Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре. Казан, 1948; Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан, 1975; Яңа гасыр поэзиясе. Казан, 1979; Тукай и его современники. Казань, 1966; Поэзия дерзаний. Казань, 1980; Многоликая лирика. Казань, 1990.

И.Х.Хәлиуллин.

ХАНБИ́КОВ Якуб Исхак улы (18.03.1928, Саратов губернасының Кузнецк өязе (хәзер Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы) Иске Кулаткы авылы – 09.05.2014, Казан), педагог, педагогия фәннәре докторы (1969), профессор (1970), ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1978, 1983). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2000).

Ульяновск педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1951), туган авы-

лы мәктәбендә укыта. 1954 елдан Казан педагогия институтында (2011 елдан — Казан федераль университетында): педагогия кафедрасы мөдире (1964–1990).

Хезмәтләре татар халкының педагогик фикер сөреше һәм Татарстанда халык мәгарифе тарихына карый. Каюм Насыйригa багышланган мәкаләләрендә галимнең фәнни-педагогик эшчәнлеге берничә чорга (1855–1870 еллар: руханилар училищесында укыту; 1871–1876 еллар: балалар өчен мәктәп ачу, анда укыту һәм китү); 1876–1902 еллар: башлыча фәнни эзләнүләр һәм тикшеренүләр белән шөгыльләнү, дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре төзү) бүлеп тикшерелә, аның татар педагогикасына зур өлеш кертүе — туган телдә укытыла торган беренче дөньяви мәктәпкә нигез салуы һәм класс-дәрес системасы белән укыта башлавы, гамәли эшчәнлеге мисалында һәм үзенең хезмәтләре аша К.Д.Ушинский эшкәрткән дидактик күрсәтмәлелек һәм аңлылык принципларын татар укытучыларына җиткерүе, шулай ук акыл хезмәтен физик хезмәт белән берләштерүне, физик хезмәтнең һәр кеше өчен кирәк булуын яклавы, татар педагогларыннан беренче булып балаларны мәктәпкә чаклы һәм укырга керү алдыннан тәрбияләүнең һәм хезмәт тәрбиясенең әһәмиятенә зур игътибар бирүе югары бәяләнә.

Педагогия Фәннәр академиясенең К.Д.Ушинский һәм А.С.Макаренко медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйри хезмәт тәрбиясе турында // Совет мәктәбе. 1962. №9; Мәгърифәтче, педагог // Татарстан коммунисты. 1975. №1; К.Насыйриның фәнни-педагогик эшчәнлеге // Совет мәктәбе. 1975. №2; Русские педагоги Татарии и их роль в развитии просвещения и педагогической мысли татарского народа. Казань, 1968; Педагог-новатор: к 150-летию со дня рождения Каюма Насыри // Советская Татария. 1974. 13 февраля; История развития педагогической мысли татарского народа. Казань, 1975.

И.Х.Хәлиуллин.

ХАНБИ́КОВА Шифа Сабиржан кызы (05.12.1928, Татарстанның Бөгелмә кантоны (хәзер Әлмәт районы) Габдрахман авылы – 09.04.2008, Казан; туган авылында җирләнә), тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1963).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң (1951), Азнакай шәһәр тибындагы посёлогында, туган авылында мәктәп укытучысы булып эшли. 1958–1986 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында хезмәт итә. Институтта эшләгән чорда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1–3 т., 1977–1981) мөхәррирләреннән берсе; татарча-русча, синонимнар, терминологик сүзлекләр төзи.

Хезмәтләре татар теле лексикологиясенә һәм лексикографиясенә карый. Каюм Насыйриның татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге турында мәкалә авторы. 1976 елда нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге (Каюм Насыйриның «Ләһҗәи татари» әсәре)» мәкаләсендә галимнең әлеге ике томлык хезмәтенең әһәмияте бәян ителә (шул чордагы татар теленең байлыгы чагылышы, авторның хәзерге татар әдәби теленең нигезен тәшкил иткән аралашу теленә юнәлеш тотуы, аңлатуның кыска һәм ачык итеп бирелеше), андагы төп аңлату принцибының синонимик ачыклау ысулыннан гыйбарәт булуы ассызыклана, гарәп һәм фарсы алынмаларының асылы аларның та-

тар телендәге тиңдәшләре аша аныклана.

Медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Синонимнар сүзлеге. Казан, 1999 (автордаш); Синонимия татарского языка. Казань, 1962; Первый толковый словарь татарского языка («Ләһҗәи татари» К.Насыри) // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

И.Х.Хәлиуллин.



В.Н.Хангилдин

ХАНГИ́ЛДИН Вәли Нигъмәтулла улы (06.06.1891, Уфа губернасының Бәләбәй өязе (хәзер Башкортстан Республикасының Благовар районы) Иске Сынлы (Сынны) авылы – 02.06.1971, Казан), тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1934), ТАССРның атказанган фән эшлекләсе (1961).

«Галия» мәдрәсәсендә (Уфа шәһәре, 1911–1914) белем ала. 1915 елдан мәктәп укытучысы булып эшли, 1917 елдан — казакъ теле укытучылары әзерләү курсларында, 1918 ел уртасыннан — рус-башкорт ятимнәр йортында, татар-башкорт педагогия техникумында, Өлкә башкорт педагогия техникумында уку-укыту бүлеге мөдире (Пермь, Акмулла, Уфа, Екатеринбург шәһәрләре). 1931–1955 елларда Казан педагогия институтында эшли. Бер үк вакытта, 1945–1951 елларда, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар теле секторы мөдире вазифаларын башкара.

Хезмәтләре татар теле морфологиясе, синтаксисы, грамматикасы һәм сөйләм культурасына карый. «Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеге»н (1950) төзүчеләрнең берсе, башлангыч сыйныфлар өчен татар һәм башкорт телләре дәреслекләре һәм программалары, Каюм Насыйриның татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге хакындагы мәкаләләр авторы. «*Совет әдәбияты*» (1945) журналында басылган «Каюм Насыйри грамматикаларында татар теле нигезләре» мәкаләсендә башлыча галимнең «*Әнмүзәҗ*» хезмәте тикшерелә, анда гади һәм кушма җөмләләр синтаксисының башлангыч алуы яктыртыла. К.Насыйриның тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары җыентыгында (1948) урнаштырылган «Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе» мәкаләсендә галимнең татар лексикографиясе үсешенә керткән өлеше, аның «Татарча-русча лөгать китабы» (1878), «Русча-татарча сүзлек», «*Ләһҗәи татари*» (1895–1896) сүзлекләре һәркайсы аерым тикшерелә. Лексикография өлкәсендә К.Насыйриның сүзлекләр төзегәндә өч максатны: русларга — татар телен, татарларга рус телен өйрәтү («Татарча-русча лөгать китабы»; «Полный русско-татарский словарь», 1892), татарларга һәм башка кызыксынучыларга шул чор татар әдәби телен өйрәтү һәм аны лексик-стилистик яктан баету, аның лексик нормаларын эшләү (терминологик сүзлекләр: төрле фәннәр буенча кулъязмалар хәлендә сакланган латинча-гарәпчә биология терминнары сүзлеге, татарча-латинча-русча ботаника терминнары сүзлеге, татарча биология терминнары сүзлеге, русча-латинча-татарча ботаника терминнары сүзлеге, гарәпчә-татарча-латинча гомуми терминнар сүзлегенең башлангычы; аларның бер өлеше галимнең басылып чыккан кайбер хезмәтләренә, мәсә-

ләп, «*Гөлзар вә чәмәнзар*», «*Буш вакыт*» әсәрләренә кертелгән) максатларын күздә тотуы икърар ителә. Сүзләрне аңлату юлында К.Насыйриның, төрле материал һәм чаралардан файдаланып, берничә төрле алым (сүзләрне турыдан-туры татарча яки татарчалашкан ишләре яисә синонимнары белән аңлату: мәсәлән, абынмак — абаланмак, сөртенмәк, төртелмәк; гарәп, фарсы сүзләре белән генә, яки аларга татар сүзләрен дә аралаштырып тәрҗемә итү: эш — гамәл, шөгыль; татар, рус һәм гарәп сүзләре белән тәрҗемә: утыргыч — урындык, скамья, түнгәк; сүзнең анык синонимнары, ишләре яки яраклы тәрҗемәләре табылмаганда, җәелдерелгән аңлатмалар бирү: абага — урманда үсә торган бер мәшһүр нәбатьдыр; кирәгенә карап, сүзләрнең мәгънәләрен һәм мәгънә төсмерләрен ачыклау, аныклау, аларның кулланылган урынарын күрсәтү өчен «Ләһҗәи татари»га күп кенә мисаллар, иллюстрация материаллары кертелү) куллануы күрсәтелә. Галим төзегән сүзлекләрнең татар әдәби теле үсеше һәм алдагы чорларда барлыкка килгән сүзлекләр өчен ышанычлы җирлек булу әһәмияте ассызыклана, аерым алганда, «Ләһҗәи татари» аңлатмалы сүзлеге татар телен тарихи үсештә, аеруча аның лексика тармагын өйрәнүдә бердәнбер тулы чыганак буларак бәяләнә.

Хезм.: Татар теленең грамматикасы һәм орфографиясе. Казан, 1934; Каюм Насыйри грамматикаларында татар теле синтаксисы нигезләре // Совет әдәбияты. 1945. № 2; Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Татар теле грамматикасы: морфология буенча очерклар. Казан, 1954; Татар теле грамматикасы. Казан, 1959; Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан, 1976.

Әд.: Казанская лингвистическая школа. Казань, 2008.

И.Х.Хәлиуллин.

ХАРИ́СОВ Фираз Фәхразый улы (24.05.1952, Башкортстанның Яңавыл районы Истәк авылы), педагог, педагогия фәннәре докторы (2001), профессор (2001), РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2004), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2008), ТРның атказанган мәктәп укытучысы (2002). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1997).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, 1978–1987 елларда Казанның Ленин район Советы Башкарма комитетында эшли. 1987 елдан Казан педагогия институтында (1994 елдан Казан педагогия университеты, 2005 елдан Татар гуманитар-педагогика университеты): проректор (1991–1998), рус мәктәпләрендә татар телен укыту кафедрасы мөдире (2000–2009). 2011 елдан Казан федераль университетында: татаристика, тюркология һәм этномәдәни белем бирү фәнни-мәгариф үзәге җитәкчесе урынбасары, 2012 елдан хәзерге заман татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы мөдире.

Хезмәтләре татар телен татар булмаганнарга укыту методикасы мәсьәләләренә карый. Шулай ук ул рус мәктәпләренең 1–5 сыйныфлары өчен татар теле буенча дәреслекләр җыелмасы (Ч.М.*Харисова* белән берлектә), уку-укыту сүзлекләре авторы.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре, Казан, 2002; Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту



Ф.Ф.Харисов



Ч.М.Харисова

программасы (татар балалары өчен). Казан, 2011 (автордаш); Психолого-педагогические и лингвистические основы обучения татарской устной речи в русской школе. Казань, 1998; Развитие этнорегионального образования: история и современность. М., 2011 (автордаш).

Әд.: Харисов Фираз Фахразович: Биобиблиографический справочник. Казань, 2012.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ХАРИ́СОВА Чулпан Мөхәррәм кызы (17.03.1953, Татарстанның Кукмара районы Зур Сәрдек авылы), педагог, педагогика фәннәре докторы (2002), профессор (2003), ТРның атказанган мәктәп укытучысы (2003), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2008). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (1997).

Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, 1975–1979 елларда Зур Сәрдек урта мәктәбендә укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1979 елдан Казан педагогия институтында (1994 елдан Казан педагогика университеты, 2005 елдан Татар гуманитар-педагогика университеты) татар теле кафедрасында укыта. 2011 елдан Казан федераль университетында хәзерге заман татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры.

Хезмәтләре татар телен укыту методикасына карый. Ул шулай ук рус мәктәпләренең 1–5 сыйныфлары өчен татар теле буенча дәреслекләр җыелмасы (Ф.Ф.*Харисов* белән берлектә) авторы.

ТР Мәгариф һәм министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар теле: татар урта гомуми белем бирү мәктәпләренең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, 2006; Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан, 2010; Методика обучения русскому произношению учащихся начальных классов русских школ. Казань, 2000; Татарский язык. Справочник. Казань, 2014.

Әд.: Харисова Г.Ф. Татар дәүләт гуманитар-педагогик университеты һәм аның галимнәре: Чит телле аудиториядә татар теле дәресләре өчен дидактик материаллар. Казан, 2009; Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Тел хәзинәсе сагында // Ватаным Татарстан. 2003. 21 март.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ХӘБИБУ́ЛЛИНА Закирә Нури кызы (14.09.1936, Башкортстанның Туймазы районы Үрнәк авылы – 28.11.2022, Казан), педагог, педагогика фәннәре кандидаты (1997), СССР Халык мәгарифе отличнигы (1980), ТРның атказанган укытучысы (1986). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2008).

Казан педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң (1959), Октябрь (хәзер Нурлат) районы Кизләү урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта. 1963 елдан Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының (2005 елдан ТРның Мәгарифне үстерү институты) татар теле һәм әдәбияты кабинеты методисты, бер үк вакытта,



З.Н.Хәбибуллина

1963–1991 елларда шунда ук мәдир вазифасын башкара, 1992–2012 елларда фәнни хезмәткәр булып эшли, 2000 елдан доцент.

Хезмәтләре балаларга татар теле һәм әдәбиятын укыту, өйрәтү мәсьәләләренә карый. Методик кулланмалар, татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре авторы.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

Хезм.: Рус мәктәбендә татар балаларына әдәбият укыту. 8 нче сыйныф: укытучылар өчен методик кулланма. Казан, 2003 (автордаш); Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек. Казан, 2005 (автордаш); Татар теле һәм әдәбияты. Үрнәк программалар: Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен. 1–11 нче сыйныфлар. Казан, 2011 (автордаш).

Әд.: Дәрзаман Ж. Кыйбла. Азат хатын, 1990. № 5; Кто есть кто: авторы издательства «Магариф». Казань, 2002.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ХӘБИБУЛЛИ́НА Люция Бәдретдин кызы (07.12.1926, Төмән өлкәсенең Вагай районы Тугыз авылы), педагог, язучы, журналист, РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы (1966), ТРның атказанган укытучысы (2023), ТР Журналистлар берлеге әгъзасы (2001). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2016).



Л.Б.Хәбибуллина

Тобол педагогия училищесын тәмамлаганнан соң (1944), Вагай районы Кәешкүл авылы мәктәбендә математика укыта, бер үк вакытта, 1944–1948 елларда Тобол укытучылар институтының физика-математика факультетында укый, Казан педагогия институтының филология (1950), тарих-филология (1965) факультетларын тәмамлый. 1950 елдан Төмән районының Кыштуплы, 1953–1997 елларда Акъяр мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

Фәнни-педагогик эшчәнлегендә җирле материаллардан файдалану мәсьәләләре карала. Ул эшләгән чорда Акъяр татар урта мәктәбе Төмән өлкәсенең милли-мәгърифәт үзәгенә әверелә; мәктәптә ел саен Татарстанның күренекле әдипләре (Зәки Нури, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Атилла Расих, Шәүкәт Галиев һ.б.) белән очрашулар, конференцияләр, семинарлар үткәрелә. Аның әдәби, публицистик, гыйльми тикшеренүләрне үз эченә алган китаплары, шул исәптән «Язмыш сукмагы» (2002) җыентыгы, ике томлык «Туган як әдәбияты» (2002, Каюм Насыйри исемендәге бүләк), «Себердә татар мәгарифе (XX гасыр)» (2008) басмалары дөнья күрә. Алар туган якның сүз сәнгатен, мәгарифен өйрәнүдә билгеле бер үрнәк, өлге булып тора. «Туган як әдәбиятының бурычы — җирле язучыларның әсәрләрен бала күңеленә сеңдерүдән, аларның мәгънәсен, нәфислеген төшендерү, туган халкына, аның теленә, әдәбиятына, мәдәниятенә, яшәү рәвешенә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт

тәрбияләүдән, укучыларда әдәби әсәрләрне күбрәк укырга теләк уятудан һәм тәрбияләүдән гыйбарәт», — дип яза ул.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе, Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Хезм.: Туган як әдәбияты. 5–11 нче класс укучылары өчен уку кулланмасы: 2 кисәктә. Төмән, 2002; Себердә татар мәгарифе (XX гасыр). Төмән, 2008.

Әд.: Алишина Х. Туган як әдәбияты // Мәгариф. 2003. № 5; Татары земли сибирской. Казань, 2005.

Ф.Г.Камальтдинова.

ХӘЙДӘ́РОВА Роза Зәки кызы (26.08.1953, Татарстанның Актаныш районы Теләкәй авылы), педагог, педагогика фәннәре кандидаты (1999), ТРның атказанган укытучысы (2004), ТРның Халык мәгарифе отличнигы (1994). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2022).

Минзәлә педагогия училищесын (1973), Казан университетының тарих-филология факультетын (1978), Казан педагогия институтының тарих факультетын (1984) тәмамлый. 1978–1987 елларда Актаныш районының Теләкәй, Мөслим районының Шуран урта мәктәпләрендә тарих, татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 1987–1990 елларда Чаллы шәһәре мәгариф бүлеге методисты. 1990 елдан Чаллы өзлексез педагогик белем бирү институты методисты, милли мәгариф факультеты деканы (1992–1998), телләрне коммуникатив технология нигезендә өйрәнү лабораториясе мөдире (1999–2001), филология кафедрасы мөдире (2002–2010). 2011 елдан Чаллы социаль педагогик технологияләр һәм ресурслар институтының «Рус телле балаларга татар теле укытуның теоретик һәм методик нигезләре» лабораториясе мөдире. 2019 елдан Коммерцияле булмаган өстәмә һөнәри белем бирү автономияле оешмасы «Менеджмент академиясе»ндә укытучы, доцент.



Р.З.Хәйдәрова

Хезмәтләре рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укытуның үзенчәлекләрен өйрәнүгә, укыту процессында яңа педагогик технологияләр куллануга, уку-укыту–методик комплекслар һәм методик әсбаплар әзерләүгә карый. Укыту-методик проблемаларга багышланган хезмәтләр авторы. Ул 1–11 сыйныфлар өчен уку-укыту-методик комплекты әзерли. Әлеге комплект үз эченә һәр сыйныф өчен дәреслек, укытучы өчен методик ярдәмлек, дәресләрнең тематик планын, башлангыч сыйныф укытучылары өчен язу дәфтәрен ала. Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина белән берлектә рус телендә гомум белем бирү оешмаларында татар телен өйрәнүчеләр өчен төзелгән һәм «Күңелле татар теле» сериясендә дөнья күргән дәреслекләре иң актив кулланылучы уку әсбаплары. Алар телне аралашу аша өйрәнү, ситуатив күнегүләр кулланып, укучыларның актив фикерләү эшчәнлеген булдыру, эчтәлек сайлау, күнегүләрнең мотивлашкан булуын тәэмин итү, грамматика өйрәнүнең академик тәртибеннән китеп, функциональлек принцибын куллану — уку-укыту-методик комплекты төзелешенең төп принципларын тәшкил итә.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Хезм.: Мин татарча сөйләшәм / Я говорю по-татарски. 1–4 классы: сборник ситуативных упражнений для русскоязычных учащихся. Н. Челны. 2019 (автордаш.); Мин татарча сөйләшәм / Я говорю по-татарски. 5–9 классы: сборник ситуативных упражнений для русскоязычных учащихся. Н.Челны, 2019 (автордаш); Рус телле балаларның «Татар теле» предметы буенча сөйләшә белү күрсәткечләре һәм аларны тикшерү биремнәре. Казан, 2020; Примерная рабочая программа учебного предмета «Государственный язык Республики Татарстан — татарский язык» для 5–9 классов основного общего образования. Казань, 2022 (автордаш).

Ф.Г.Камальтдинова.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Айдар Гарифетдин улы (10.02.1967, Казан), ислам белгече, фәлсәфәче, укытучы, тәрҗемәче, философия фәннәре кандидаты (2004).

Мәскәү энергетика институтының Казан филиалында (1984–1985), Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә (1988–1990, 1992–1994), Ташкент Шәрыкшиналык институтында (1990–1992) белем ала. 1992–1996, 1997–2004 елларда Татар гуманитар көллиятендә, 2005–2007 елларда Татар гуманитар-педагогик университетында өлкән укытучы булып эшли. 2002 елдан ТР Фәннәр академиясенең Тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр. 2021 елдан Мәскәү ислам институты каршындагы Муса Бигиев исемендәге Фәнни тикшеренү мәркәзе мөдире.

Хезмәтләре гарәп теле, Шәрекъ әдәбияты, тәрҗемә теориясенә карый. Фәнни эшчәнлегендә ислам дине белеме, Муса Бигиевнең тормыш юлы һәм язма мирасы, дини һәм иҗтимагый фәлсәфә, татар иҗтимагый фикере тарихы, татар мәгърифәтчелеге буена тикшеренүләр зур урын били. Ул



А.Г.Хәйретдинов

шулай ук гарәп телендә уку-укыту буенча кулланмалар, шулай ук публицистик язмалар авторы.

А.Хәйретдинов Каюм Насыйриның мирасын таныту һәм өйрәнү юнәлешендә зур эш алып бара. Мәгърифәтчегә багышланган чараларда, конференцияләрдә катнаша. Р.*Шәфигуллина* белән автордашлыкта Каюм Насыйриның 130 ел дәвамында билгесезлектә яткан «Мифтах әл-Коръән» кулъязмасын бастырып чыгара.

Хезм.: Каюм Насыйриның 130 еллык кулъязмасы: Коръән өйрәнү тарихы / Татарское рукописное наследие: изучение и сохранение: материалы всероссийской научно-практической конференции, посвященной 130-летию С.Вахиди. Казань, 2017 (автордаш)); Трактаты Каюма Насыри «Мифтах аль-Куран» // Насыри К.Мифтах аль-Куран. В 2. т. / Казань, 2015; «Мифтах аль-Куран» Каюма Насыри: Первый в мусульманском мире конкорданс Корана // Ислам в современном мире. 2016. №12 (1); Наследие выдающегося татарского ученого-энциклопедиста Каюма Насыри в свете восточной и западной научной парадигмы // Вестник Библиотечной ассамблеи Евразии. 2018. №1 (автордаш).

Ф.С.Гыйниятуллина.

ХӘЙРИ́ (Хәйруллин) Әнвәр Нәҗип улы (02.12.1947, Татарстанның Аксубай районы Шәрбән авылы – 20.07.2014, Казан), филолог, текстолог, язучы, ТРның атказанган фән эшлеклесе (1999), ТРның һәм РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (1991, 2008), Кол Гали исемендәге халыкара бүләк (1994), ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең

Җамал Вәлиди исемендәге бүләге (2008), Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге бүләк (2010), әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә М.А.Шолохов исемендәге халыкара бүләк (2014) лауреаты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2004).



Ә.Н.Хәйри

Казан университетын тәмамлый (1973). 1974–1991 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1991–1995 елларда — «Мирас» журналында, 1996 елдан ТР Милли китапханәсендә эшли. Бер үк вакытта, «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе белән хезмәттәшлек итә.

Хезмәтләре татар халкының рухи мәдәнияте, Идел буенда ислам таралу тарихы, педагогика мәсьәләләренә карый. Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Риза Фәхретдин, Галимҗан Ибраһимов һәм башкаларның хезмәтләрен текстологик басмага әзерли (кереш сүз, шәрехләмәләр). «Әхмәд ибне Фазланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә сәяхәте вакытында язылган бәян» (2013) китабы авторы.

Каюм Насыйри турында «Мәдәни җомга», «Заман–Татарстан», «Шәһри Казан» газеталарында басылган мәкаләләрендә галимнең тормыш юлы бәян ителә, фәннең төрле тармакларын һәм халык кәсепләрен өйрәнү һәм гамәлдә куллану буенча куйган эшчәнлеге (медицина, педагогика, тел белеме, тарих, зәркәнчелек, төрле эш кораллары, музыка уен кораллары ясау һәм аларда уйнау сәләте) күздән кичерелә. Ә.Хәйри тарафыннан ул вакытта дөньяга чыгарылмаган хәлдә ТР Милли музее әдәби бүлегенең кулъязмалар фондында сакланган «Казан» кулъязмасы анализланып, Казан шәһәренең урыны, урамнары, бүленеше, халкының тормыш-көнкүреше һәм кәсепләре, мәчетләре, аларның кыскача тарихлары, имамнары турындагы кызыклы мәгълүматларга; нәкъ менә Каюм Насыйриның беренче булып, татар теле үзенчәлекләрен искә алып, гарәп язмасындагы 28 хәреф янына татар хәрефләре өстәп, татар әлифбасын камилләштерү мәсьәләсен күтәреп чыгуы югары бәяләнә. 1976 елда нәшер ителгән «Атаклы мәгърифәтче-демократ Каюм Насыйри» җыентыгында урнаштырылган «Насыйри һәм Мәрҗани» мәкаләсендә ике атаклы галимне Әхмәтзәки Вәлидидән башланган дошмани дәрәҗәдә каршы куюларның нигезсезлеге, алар арасындагы каршылыкның фәкать Хисаметдин Мөслимигә һәм аның «Тәварихе Болгария» әсәренә карата икесе ике карашта торуларыннан гына гыйбарәт булуы; Мостафа Чутайның Казан университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендәге галимгә нисбәтле калын гына «Шырпы, ягъни күрелмәгән һәм ишетелмәгән хәбәрләр язылыр» кулъязма дәфтәрендә (1871) урын алган 65 юллык Мәрҗанигә мәдхияле шигыренә һәм К.Насыйриның ТР Милли музее әдәби бүлегенең кулъязмалар фондында сакланган кулъязмасына нигезләнеп, мәгърифәтче галимнең Мәрҗани хакында югары фикердә торуы дәлилләнә.

Хезм.: Бер кулъязма эзеннән: Каюм Насыйриның тууына 160 ел тулу уңаеннан // Социалистик Татарстан. 1985. 14 февраль; Каюм Насыйри Казан турында // Шәһри Казан. 1991. 28 февраль; Милләтне нур-

ландырган шәхес // Заман–Татарстан. 1995. 10 февраль; Бабайларны им-том дәвалаган. Каюм Насыйри хезмәтләрендә халык медицинасы мәсьәләләре // Мәдәни җомга. 2005. 11 февраль; Насыри и Марджани // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

Әд.: Хуҗин Ф. Күпкырлы галим // Казан утлары. 2008. № 5.

И.Х.Хәлиуллин.

ХӘКИ́МОВА Рабига Афзал кызы (1902, Казан губернасының Чистай өязе (хәзер Татарстанның Чистай районы) Яуширмә авылы. — 1952, Казан), тел белгече, педагог, филология фәннәре кандидаты (1944); Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген оештыручы.

Казан педагогия институтын тәмамлый (1940). 1917–1927 елларда Чистай өязенең Иске Татар Әдәмсуы, Әлки, Каргалы, Мөслим, Чистай, Кизләү авылларының башлангыч мәктәпләрендә укыта. 1928 елда Казанга килә, 5 нче тегү фабрикасына эшкә урнаша. 1930–1932 елларда Татар коммунистлар университетында укый, бер үк вакытта ВКП(б) район комитетында инспектор вазифаларын башкара. 1933 елда Сарман машина-трактор станциясенең сәяси бүлекчәсенә эшкә җибәрелә. 1935–1936 елларда Татарстан радио комитетында сәяси мөхәррир. 1936–1940 елларда Казан шәһәренең 80 нче мәктәбендә укытучы булып эшли. 1944 елдан Казан университетында укыта башлый, шул ук елда кафедра мөдире итеп билгеләнә, аның тырышлыгы белән татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. 1948 елда университет тарафыннан оештырылган татар-мишәрләрнең телен өйрәнүгә багышланган диалектологик экспедицияне җитәкли.

Хезмәтләре татар тел белеменә һәм аның тарихына карый. Каюм Насыйриның татар теле өлкәсендәге эшчәнлегенә багышланган «Каюм Насыйров — тел белгече» мәкаләсендә (1948) 18 йөз ахыры – 19 йөзнең 1 нче яртысында, тел белеме өлкәсендә галимнең эшчәнлегенә кадәрге чорда (18 йөз ахыры – 19 йөзнең 1 нче яртысында) татар теленең өйрәнелү халәтенә тукталып, Сәгыйть Хәлфиннең руслар өчен беренче «Татар әлифбасы (хәрефләрләрнең, иҗекләрнең тәфсилле тасвирламасы белән)» (1774), Иосиф Гигановның «Татар теле грамматикасы» (1801), «Рус-татар сүзлеге» (1804), Ибраһим Хәлфиннең «Татар теле әлифбасы һәм грамматикасы (гарәпчә уку кагыйдәләре белән)» (1809), Александр Троянскийның «Кыскача татар грамматикасы» (1814), «Татар теле һәм анда кулланылучы кайбер гарәп-фарсы сүзләре сүзлеге» (1833), Мирза Казимбәкнең «Төрек-татар теле грамматикасы» (1839), Мартиниан Ивановның «Татар теле грамматикасы» (1842), «Татар хрестоматиясе» (1842), Мөхәммәдгали *Мәхмүдовның* «Татар телен өйрәнү өчен гамәли кулланма» (1857), Салихҗан Кукляшевның «Татар хрестоматиясе» (1859) хезмәтләре күздән кичерелә, К.Насыйри әлгәрләренең татар теле лексикасын өйрәнүгә нигез салулары икърар ителә; галимнең алар эшен дәвам итүе, шул ук вакытта татарлардан беренче тапкыр һәм, гомумән, тюркологлар арасында беренчеләрдән буларак татар телен төрле яклап фәнни өйрәнүне нигезләве, техник фәннәр, авыл хуҗалыгы фәннәре, гигиена өлкәсендә терминология булдыруга башлангыч



Р.А.Хәкимова

бирүе белән алардан аерылып торуы ассызыклана. К.Насыйриның «*Әнмүзәҗ*» (1895) хезмәте тирән анализланып, аның татар телен өйрәнүдәге кайбер казанышларны татарларның киң даирәсенә җиткерүе, туган телен башка телләр, шул исәптән рус теле белән багланышлардан аерымламавы, рус телен татар яшьләре арасында популярлаштыруда зур роль уйнавы турында нәтиҗә ясала.

«Почёт билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар теле орфографиясе сүзлеге. Казан, 1940; Тел белән аң, эчтәлек белән форма арасындагы бәйләнеш // Совет мәктәбе. 1959. № 3; Каюм Насыри как языковед // Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы научных сессий, посвященных 120-летию со дня рождения). Казань, 1948.

И.Х.Хәлиуллин.

ХӘЛИ́МОВА Кадрия Борис кызы (12.12.1997, Татарстанның Чаллы шәһәре), тарихчы, музей хезмәткәре.

Казан федераль университетын «төрки-мөселман дөньясы сәнгате тарихы» белгечлеге буенча тәмамлаганнан соң (2021), Казан Кремлендә «Дәүләтчелек тарихы музее»нда фәнни хезмәткәр, Спас манарасы музеенда баш фәнни хезмәткәр булып эшли. 2023 елдан Казандагы Каюм Насыйри музее мөдире.

К.Хәлимова җитәкчелегендә музейда К.Насыйриның фәнни хезмәтләрен һәм мирасын популярлаштыру максаты белән мәдәни-агарту эшчәнлеге алып барыла. Тематик лекцияләр, экскурсияләр, балалар өчен остаханәләр оештырыла. К.Насыйри шәхесен таныту максатыннан музей мәйданында «Миллиард татар» сайты белән берлектә лекторий проекты гамәлгә ашырыла. Музей К.Насыйри исемен саклауга һәм мәңгеләштерүгә зур өлеш



К.Б.Хәлимова



М.З.Хәмидуллина

кертә. Җитәкчелек тарафыннан галим соңгы елларында яшәгән йорт урынында торгызылган музейны комплекслы музей дәрәҗәсендә тотуга зур игътибар бирелә. Ел саен татар халкының күренекле шәхесләре катнашында мәгърифәтченең туган көнендә (14 февральдә) түгәрәк өстәлләр, вафат булган көнендә (20 августта) каберенә зиярәт кылу оештырыла.

Ф.Г.Камальтдинова.

ХӘМИДУ́ЛЛИНА Мәрзия Зәки кызы (04.04.1950, Татарстанның Саба районы Елыш авылы), педагог, РФнең халык мәгарифе отличнигы (1994), ТРның атказанган укытучысы (2000). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2012).

Казан педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлый (1974). Хезмәт юлын Татарстанның Теләче районы Иске Җөри мәктәбендә өлкән әйдәман һәм укытучы буларак башлый. 1969 елдан тәрбияче, Казан шәһәренең 285 нче мәктәпкәчә белем бирү учрежденисе методисты, 1974 елдан ТАССР Мәдәният министрлыгының мәдәният хезмәткәрләре белемен күтәрү курслары методисты булып эшли. 1978 елдан Казан шәһәренең 78 нче урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта. 1992–2018 елларда әлеге мәктәптә мил-

ли мәгариф буенча директор урынбасары вазифасын башкара.

Эшчәнлегендә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының иҗади үсеше өчен шартлар тудыруга һәм камилләштерүгә аеруча күп көч куя, шулай ук иҗтимагый оешмалар (Бөтендөнья татар конгрессы һ.б.) белән хезмәттәшлек итүгә зур игътибар бирә. Бер үк вакытта, М.Хәмидуллина татар һәм рус мәктәпләрендә укучы балалар өчен язылган дәреслекләр, милли мәгариф буенча директор урынбасарлары өчен беренче методик ярдәмлекләр авторы. Аның дәреслекләре буенча Татарстан һәм Россия мәктәпләре укучылары белем ала, укытучылар һөнәри белем дәрәҗәсен күтәрә. Дәреслек һәм методик әсбапларында Каюм Насыйри традицияләре дәвам иттерелә.


«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале һәм Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар теле. Рус телендә гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек (автордаш). Казан, 2015; Татар теленнән дидактик материаллар. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5–7 сыйныфлары. Укытучылар өчен кулланма (автордаш). Казан, 2015; Татар теле. Төп гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен электрон дәреслек (автордаш). Казан, 2016.

Ф.С.Гыйниятуллина.

«ХИСАПЛЫ́К» («Хисаплык ягъни гыйльме хисап кагыйдәләре яки арифметика вә һәм хисаплык мәсьәләләре»), арифметика буенча уку әсбабы. Каюм Насыйри тарафыннан языла һәм 1873 елда Казан университеты басмаханәсендә бастырыла.

Аның язылу сәбәбен һәм фәннең асылын: «Бу вакыткача гыйльме хисап фәнендә безнең үз телемез белән бер дә язылган китап юклык сәбәпле истыйлах сүзләре һәм юк. ... Бәс, бу гыйльме хисап голүме риязыядан [математика фәненнән] бер фәндер ки, гыйльме хисапка кәма һүә монсариф [тулысынча бирелгән] булган кеше игъдады мәгълүмәдән [әзерлеге беленгән] мәҗһуләт гадәдияне [билгесез санны] истихраҗ [чыгару] кылмага кадәр булыр вә дәхи гыйльме хисапның мәузугы [проблемасы] маддәдә хасыйл булгучы гадәдләрдер, ягъни үлчәү саннары димәгемез кебек саннардыр», — аңлата. Әүвәл сүз бер, ике, өч урынлы, аннары катлаулы саннар турында бара. Соңыннан кушу (җыю),



К.Насыйри. «Хисаплык». Казан, 1873.

алу (аеру), тапкырлау (сугу), бүлү кебек гамәлләр өйрәтелә. Шул ук вакытта әбҗәд системасы да китерелә. Үлчәү саннары, вакландыру ысуллары күрсәтелә. Хәрефләр нигезендә саннар чыгару ысулы кызыклы. «Б не һ гә суккач (тапкырлагач) ни хасыйл булыр? И хасыйл булыр. И ничәгә йөри? И унга йөри». Өйрәтү көндәлек тормышта була торган вакыйгалар нигезендә төрле мәсьәләләр ярдәмендә башкарыла. Мәсәлән, «Бер агай 450

сумлык ашлык саткан. Аның бирәсе бар икән шул акчадан. Аны түләгән — 85 сум. Янә бер ат сатып алган — 65 сум. Тагын күпме акчасы калган?». Терминнар татар телендә бирелгән. Казан профессоры Н.Ф.*Катанов* бу китапны «татар педагогикасында файдалы яңалык» дип билгели.

Китапның икенче тулыландырылган басмасы 1899 елда нәшер ителә. Шулай ук аның кыскартылган вариантлары К.Насыйриның «Сайланма әсәрләр»ендә (1953, 1956), ике томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томында (1975), дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енең 3 нче томында (2005) да урнаштырыла.

Чыг.: Насыйри К. Хисаплык. Казан, 1873.

Әд.: Катанов Н. Хисаплык (числительница, или арифметика). Казань, 1899. Тип. ун-та. // Деятель. 1899. №6–7; Фахрутдинов Р.З. Естественно-математическое образование в педагогическом наследии Каюма Насыри: автореф. дис. ... канд. пед. наук. Казань, 2002.

Р.Ф.Исламов.

ХӨСӘЕ́НОВ Габденнасыйр (1786, Казан наместниклыгының Зөя өязе Югары Шырдан авылы – 18.03.1872, Казан губернасының Зөя өязе Югары Шырдан авылы (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылы), дин әһеле, җәмәгать эшлеклесе. Каюм Насыйриның атасы. Руханилар гаиләсендә туа, атасы Хөсәен Мукаев Югары Шырдан авылында имам булып хезмәт иткән. К.Насыйри истәлекләрендә бабасы турында: «Үз гомерендә берничә йөз Коръәнне күчереп язгандыр», — дип искә ала.

Габденнасыйр башта — Казан губернасының Казан өязе Мәчкәрә авылында данлыклы Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашыти (?–1818) мәдрәсәсендә, 1810 елдан Казанда Ак мәчет мәдрәсәсендә белем ала. 1812 елдан Югары Шырданда имам булып хезмәт итә. Соңрак, дөнья мәшәкатьләрен алга куеп, муллалык эшен калдыра; сәүдәгәрлек (кыйммәтле җәнлек тиреләре белән сату итә, ярминкәләргә йөри, Түбән Новгородтагы Мәкәрҗә ярминкәсендә дә еш була), игенчелек, умартачылык, бакчачылык, күчереп язу, тәрҗемә, төбәкчелек белән шөгыльләнә. Бер үк вакытта Г.Хөсәенов хакимият каршында авыл җәмәгатенең ышанычлы вәкиле — илдә барган вакыйгаларны аңлап, җирле чиновникларның кабинетларына кереп сөйләшә алган шәхес: киңәшче, документларны күчереп язучы, дин кардәшләренең үтенеч язуларын төзеп бирүче һәм, бәхәсле мәсьәләләр килеп чыкканда, авыл кешеләре белән хакимият органнары, мәхкәмәләр арасында арадашчы һәм яклаучы да була. Картайгач, сәүдә эшләрен ташлап, уллары ярдәм итүгә күчә.

Г.Хөсәенов, татар халкының тарихын һәм этнографиясен, татар авыллары зиратларындагы иске кабер ташларын өйрәнеп, җыелган мәгълүматларны үз дәфтәренә теркәп барган (соңыннан шул язмалардан К.Насыйри файдаланган). Бу материалларны барлау белән бергә ул Идел-Урал төбәге мөселманнары арасында бәхәсле булган ястү намазына мөнәсәбәтле язмалар (аларда ястү һәм тәрәвих намазларының кирәклеген дәлилли), фарсы гыйлем иясе Санаиның (1080–1130) «Тәбәкат әл-хаҗәт» («Мөһим эшләр тупланмасы») китабына шәрехләр һәм тәнкыйть характерындагы хезмәтләр яза. К.Насыйри этисе турындагы хатирәләрендә: «Заманның голямәсе иде. Фарси һәм гарәби язуга маһир иде. Хәзердә үз кулыннан чыккан егерме бишләп китаплар бар», — дип искә ала. Коръән телен өйрәнүне бервакытта да туктатмый. К.Насыйри әйтүен-

чә: «Үз гомерендә 1300 мәртәбә Каляме Шәриф кыйлмыштыр (ягъни Коръәнне шулкадәр укып чыккан)». Г.Хөсәенов рус телендә сөйләшә һәм укый-яза белгән, шул сәбәпле, Каюм улы әйтмешли, «үзенең заманында гайяр, үткен һәм бик зирәк адәм булгандыр. ... Бик галим кеше, хәтта заманының галлямәсе...». Нәтиҗәдә, Габденнасыйрның барлык гаилә әгъзалары да рус мәдәниятенә һәм рус кешеләренә карата ачык мөнәсәбәттә була. Г.Хөсәенов муллаларның иҗтиһад (үз фикерен белдерү) дәвере узды дигән фикерләрен кабул итми һәм, киресенчә, «Иҗтиһад — һәркемгә кирәк эш», дип санап, улларын үзе укыта.

Әд.: Заһидуллин И.К. Нәсел шәҗәрәсе кайларга китә... // Казан утлары. 2024. №7; Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Казан, 1956; шул ук. Сайланма әсәрләр, 2 томда. 2 нче том. Казан, 1975; Рәхим Гали. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Казан, 2020.

Р.В.Шәйдуллин.

ХӨСӘЕ́НОВ Әхмәт Мөхәммәтбәдигъ улы (1895–1944), Каюм Насыйриның туганы һәм аның турында истәлекләр язучы. М.М.*Хөсәеновның* улы.

Хатирәдә аның К.Насыйри белән очрашуы, мәгърифәтченең тормышы, иҗади эшчәнлеге тәфсилләп бәян ителә. Автор аның руслар белән аралашып, рус телен яхшы үзләштерүен һәм татар балаларын русча укытуын, фатирында географик карталарның, өстәл өстендә төрле язмалар, китап, газета-журналларның күп булуы, үзенә галимнең кечкенә генә глобус бүләк итүе, аны ничек русча укырга, хәрефләрне төрле төстәге кәгазьләргә язып куеп (кызыл кәгазьгә — «А», яшелгә — «Б»), шуларның сурәтен язарга өйрәтүе, төрле китаплардан шушы хәрефләрне таптыруы, аларны күрмичә яздыруы һәм хәрефләрне кушып укырга өйрәтүе турында искә ала. К.Насыйри Әхмәтне тынычландырып: «Сине руска бирәбез дип куркыталар икән, син бер дә курыкма, руслар балаларны алмыйлар, син русча да бик тырышып укы. Русларда матур сурәтле китаплар бик күп була, укый башлагач барысын да белерсең», — дип, укырга өнди. Хатирә авторы: «Аңардан укуның файдасы күп булды, укырга кергәч, мин берәр айдан ук беренчедән күчеп, икенчедә укый башладым», — дип нәтиҗә ясый.

Ә.Хөсәенов шулай ук К.Насыйриның уку китаплары, хикәяләр һәм башкаларны язуы өстенә, календарь чыгара башлавы, төрле үләннәр җыюы, табигатьне чын күңел белән сөюе һәм табигатьтән тулысынча дөрес файдалана торган кеше булуы, пылау, шәкерт салмасы, кулланма кебек ашларны үзе пешерүе хакында да яза. Моңардан тыш ул К.Насыйриның үз нәселен белеп, күп мәшәкатьләр, чыгымнар тотып өйрәнеп, 9 бабасын һәм аларның 200 гә якын токымын эзләп, шәҗәрә төзүен, рус, татар, гарәп, фарсы, хәтта немец, француз телләрен өйрәнүен икърар итә. Вафатыннан соң өендә немец, француз китаплары табылуы, бу китапларны туганы Габделмән Казанский алып китүе, ләкин аның бу китаплар һәм башка әйберләрне тиешенчә сакламавы, аларның таралып, югалып бетүе турында яза. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Каюм Насыйри турында кайбер истәлекләр // Совет әдәбияты. 1940. № 7.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ХӨСӘЕ́НОВ Мөхәммәтбәдигъ Мөхәммәтгалим улы (Бәдигъ мөэзин) (1853, Казан — 1929, шунда ук), дин

әһеле, язучы. Ә.М.*Хөсәеновның* әтисе. Каюм Насыйри белән М.Хөсәенов — туганнан туган балалары, аларның әтиләре Габденнасыйр (1786–1872) һәм Мөхәммәтгалим (1797–1874) Хөсәеновлар бертуганнар.

Казанның 5 нче таш мәчет азанчысы, ягъни мөәзине булып хезмәт итә. Аны бу вазифага мәхәллә халкы 1874 елның көзендә сайлый һәм расларга сорап Казан губерна идарәсенә мөрәҗәгать юллый. Документта аның рекрут чиратында тормавы, мәхкәмәгә тартылмавы, штрафлары булмавы, егерме бер яшьтә икәнлеге һәм даими яшәү урыны барлыгы, тиешле дини белем алганлыгы күрсәтелә. Шул елның 30 сентябрендә Уфадагы Диния нәзарәтенә барып, тиешле сынау үтә һәм бу хакта 2966 номерлы таныклык алып кайта. 1875 елның гыйнвар аенда М.Хөсәеновның документлары губерна идарәсендә тикшерелеп, әйтелгән вазифага билгеләнә.

М.Хөсәенов шул заман өчен алдынгы фикерле, киң карашлы, шигъри күңелле кеше була. Моңа аның тарафыннан язылган 1886–1894 елларны эченә алган «Бәгъзе вакыйгаи тарихия вә бәгъзе хараикъ гадәт эшләр» елъязмасы ачык дәлил. Ул хәзерге вакытта Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана. Аннан күренгәнчә, ул шәһадәтнамә, васыятьнамә, талак кылу, гариза, төрле үтенеч хатлары формаларын төзегән. Бу аның мөселман хокукыннан шактый хәбәрдар булганлыгы турында сөйли. Анда урын алган шигырьләре, бәетләре, хикәяләре, Шәрекъненең мәшһүр шагыйрьләре Фирдәүси (940–1020 яки 1030), Фөзули (1494–1556) иҗатларыннан тәрҗемәләре, үзе укыган хөтбәләрне язмача теркәп баруы аның әдәбиятка якын каләм иясе булганлыгын ачык күрсәтә. Әдәбият галиме М.*Гайнетдинов* «Гасырлар авазы = Эхо веков» журналында (2006) «Бәдигъ мәзин елъязмасы» дигән мәкаләсендә дөрес билгеләгәнчә, ул «...актив табигатьле, иҗади характерлы, күп яклы талантлы җан иясе булган, уй һәм



М.М.Хөсәенов (басып тора).

омтылышлары буенча заманының иң алдынгы фикер, иҗтиһад һәм иҗат ияләре янәшәсендә торган».

«Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге китапханәсендә К.Насыйриның «*Зөбдәт мин тәварихи әр-Русъ*» (1890) китабының бер нөсхәсендә кулдан язылган шундый сүзләр бар: «Мөхәммәтгали мәхзүм Сәгыйдов китабы. Мелла Бәдигъ мөәзин тарафыннан һәдия». Димәк, мөәзин карамагында абзасының китаплары булган. Алай гына да түгел, аның елъязмасында башка шәхесләргә җибәргән китаплар да теркәлгән. Алар арасында, мәсәлән, «Хидаят шәриф», «Тәфсире Җәләй-

лан», «Сөлләм казый», «Шәрхе викая» басмалары бар.

Әйтелгән елъязмадан аңлашылганча, М.Хөсәенов әтисеннән мирас булып калган йортта яши. Йорт берничә тапкыр янгын казасына дучар булып, хәзерге вакытта аның реконструкцияләнгән бинасында *Каюм Насыйри музее* урнашкан. К.Насыйри шушы йортта үзенең соңгы сыену урынын таба. Ул анда 1899 елдан башлап, 1902 елның 20 августына (яңа стиль белән 3 сентябренә), ягъни вафатына кадәр яши. Бәдигъ мөәзин үзе дә вафатына кадәр шул йортта яши, Казанның Яңа бистә зиратында җирләнә. Шулай ук кара: *Каюм Насыйриның вафаты*, *Каюм Насыйриның каберe*, *Каюм Насыйри яшәгән йортлар*.

Әд.: Гайнетдинов М. Бәдигъ мәзин елъязмасы // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2006. №1; Сальмушев Р. Насыйри «йорты» // Мәдәни җомга. 2019. 19 апрель.

Р.Ф.Исламов.

ХӨСНЕТДИ́НОВА Рушания Салих кызы (18.09.1953, Татарстанның Октябрь (хәзер Нурлат) районы Зирекле авылы), инженер-технолог, музей эшлеклесе, төбәк тарихчысы.

Казан химия-технология (1976), Казан педагогия (1997) институтларын тәмамлый. 1976 елдан Воронеж көйләү-эшләтү идарәсендә инженер-технолог, 1988 елдан Казандагы «Союзнефтепромхим» фәнни-тикшеренү институтында инженер булып эшли. 1993 елдан — мәдәният өлкәсендә, 1995–1996 елларда «Казан» милли-мәдәни үзәгенең тарих бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре. Р.Хөснетдинова «Татар дөньясы» күргәзмәсенең фәнни концепциясен эшли, беренче вариантының тематик структурасын, экспозиция залларының бизәлешен, темаларның ачылышын билгели, сценарийлар планын төзи.

Каюм Насыйриның исемен мәңгеләштерү йөзеннән Казанда аның шәхси музеен булдыру турында карар кабул ителә, әлеге музейның директоры итеп Р.Хөснетдинова билгеләнә (1995–2013) (кара: *Каюм Насыйри музее*). Музейның фәнни концепциясе авторы һәм сәнгать проекты автордашы, шулай ук музей әйләнәсендәге мемориаль җирлектә тарихи бакча — «Хәтер бакчасы»на нигез салучы. Бакча мәгърифәтченең өченче буын туганы Бәдигъ (Мөхәммәтбәгидъ) мөәзин оныгы Рөстәм Хөсәенов истәлекләренә таянып торгызыла һәм К.Насыйриның «Гөлзар вә чәмәнзар» («Үләнлек һәм чәчәклек») китабына нигезләнә. Бакчада исемнәре К.Насыйри хезмәтләрендә урын алган һәм шифасы аңлатылган 100 ләп дару үләне үстерелә. Бакча музей экспозициянең дәвамы булып тора, шунлыктан музей үзе дә «комплексны музей» статусын йөртә.



Р.С.Хөснетдинова

Р.Хөснетдинова К.Насыйриның фәнни китапханәләрдә, архивларда саклана торган тупланмаларын, аның мирасына багышланган хезмәтләрне өйрәнә, мәгърифәтченең туган төбәге — Яшел Үзән районының 14 авылына фәнни экспедицияләр оештыра, Казанның Иске Татар бистәсендә К.Насыйри белән бәйле урыннарны барлый. Әлеге эшләр барышында аның җитәкчелегендә 2 меңнән артык саклау берәмлегеннән торган музей фонды туплана. Экспозицияләр К.Насыйриның тормышын һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеген яктырта. Музейда 19 йөз мәгърифәтчеләре Шиһабетдин *Мәрҗани*, Хөсәен Фәезханов, Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфиннәргә багышланган материаллар да урын ала.

Музей директоры буларак, Р.Хөснетдинова К.Насыйриның мирасын мәңгеләштерү буенча күпкырлы эш

алып бара. Музей мәйданнарында күргәзмәләр, конференцияләр уздырыла. Мәгърифәтче галимнең тууына 175 ел тулу уңаеннан уздырылган конференциядә музей фонды тупланмаларыннан торган күргәзмә оештырыла, әлеге чарада музей директоры аның кураторы буларак чыгыш ясый. Р.Хөснетдинованың Насыйрилар нәселе туганлык җепләрен барлау һәм шәҗәрәләр төзү юнәлешендәге эшчәнлеге аерым эзләнү тармагын тәшкил итә. Ул буыннарны ачыклап, аларның дәвамчыларын эзләп таба, күбесе белән якыннан аралаша. Яздырып һәм язып алган истәлекләр, сакланып калган кулъязмалар, матди мирас музейда урын ала. Казан шәһәре мәгариф идарәсе, мәктәпләр, югары белем бирү оешмалары белән тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә, директор музейның шәһәр мәдәни киңлегендә үзенең лаеклы урынын алуына ирешә.

Р.Хөснетдинова К.Насыйриның күпкырлы эшчәнлеген халык хәтерендә яңарту юнәлешендә дә нәтиҗәле эш алып бара. Аның мәгърифәтчегә багышланган язмалары Татарстан матбугаты битләрендә дөнья күрә.

Казан шәһәре мэрының һәм Башкарма комитеты мәгариф идарәсенең Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм бабай ядкаре // Ватаным Татарстан. 1997. 21 ноябрь; Андыйлар табигатьтә сирәк очрый // Казан утлары. 1998. №4; Кыйбла // Мирас. 1999. №12; Музейный подход к изучению и пропаганде истории татарского народа и Татарстана // Заказанье: проблемы истории и культуры. Казань, 1995.

Әд.: Кавеева Ф. Мы вышли в сад // Республика Татарстан. 2012. 15 мая.

Ф.С.Гыйниятуллина.

әл-ХУҖАШӢ Насретдин (?–?), дин эшлеклесе, публицист, тәнкыйтьче; Каюм Насыйри турында истәлек язучы. Аның хатирәсе беренче мәртәбә «Шура» журналында (1912) дөнья күрә. Аннан соң әдәбиятчы Фатыйма *Ибраһимова* тарафыннан «Әдәби мирас» сериясенең 3 нче китабында (1996) бастырыла.

Әл-Хуҗаши үзенең истәлегендә Казанга шәкерт булып килгән көннәрендә мәгърифәтче галим К.Насыйри турында башкалар аркылы белүе, мәдрәсәләрдә «Тәүзыйх» китабын укучы сыйныф шәкертләреннән һәм мәдрәсәләрдә тулы уку курсын тәмамлап, хәлфәлеккә урын көтеп торучылардан К.Насыйрига карата начар мөнәсәбәттә булулары турында ишетүе, үзенең дә шулар тәэсиренә бирелеп мәгърифәтченең китапларын укудан мәхрүм калуы, ләкин вакыт үтү белән К.Насыйрига карата фикеренең уңай якка үзгәрүе, күңелендә булган нәфрәт урынына китапларына да мәхәббәт уянуы хакында тәфсилләп яза.

1901–1902 уку елында Мәхмүдфуад Туктаров, Габдерәүф Ниязбаев белән галимне эзләп табып очрашуларын, мәгърифәтченең өендә булуын, китапларының күплеге һәм төрле эш кораллары булуга игътибар итүен искә ала. Хатирәдә түбәндәге юллар бар: «...Бу көндә нинди китап язып мәшгуль буласыз?» — дип сорагач, утырган диванының бер башыннан көрпәсен кайтарып, зур кулдан Коръән хәҗеменедә тәхминән 750 сәхифәлек яңы кәгазьле, тышсыз кулъязма бер китап чыгарды вә, сүзендә дәвам итеп, «Буңа әле исем куйганым юк. Буның илә Коръән Кәримнең һәр аятен вә һәр кәлимәсен табып булачак. Минем язып торган бу китабым мәшәкатьләрнең барсын да бетерәчәк. Инша Аллаһ, тиз тәмам булыр һәм озакламый басылып чыгачак...». Әл-Хуҗаши К.Насыйриның, тормышы авыр булуга да карамастан, татар милләтенә агартыр өчен

бөтен көчен куюын, татар халкының киләчәге якты, гыйлемле булсын өчен тырышуын ассызыклый, шулай ук «Мине Аллаһ китап язар өчен яраткан, бу көннән аны язмый утыру Аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», дигән сүзләрен горурлык хисе белән искә ала. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри илә мосахәбә (хатирә дәфтәремнән) // Шура. 1912. № 24; «Алла мине язар өчен яраткан...» // Мәгърифәт. 1995. 11 февраль; Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри белән мосахәбә // Әдәби мирас. Казан, 1996. 3 нче кит.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ХУҖИӘХМӘТОВ Әнвәр Нуриәхмәт улы (30.07.1952, Татарстанның Куйбышев (хәзер Спас) районы Йолдыз авылы), педагог, педагогика фәннәре докторы (1997), профессор (1998). ТАССРның, РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы (1984, 1986), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1999), РФнең югары белем бирү мактаулы хезмәткәре (2001); Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге бүләге (1985) иясе. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2001).

Казан университетын (1974), Россия социаль-гуманитар институтын (1996) тәмамлый. 1976 елдан Куйбышев районының Яңа Бәрән (Яңа Рәҗәп, хәзер Чәчәкле авылы) урта мәктәбендә укытучы, 1978 елдан мәктәп директоры булып эшли. 1988 елдан ТР Мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр бүлеге мөдире вазифасын башкара. 1993 елдан Татар гуманитар-педагогика университетында укыта. 2011 елдан Казан федераль университеты Педагогика һәм психология институтының педагогика кафедрасы мөдире.



Ә.Н.Хуҗиәхмәтов

Хезмәтләре мәктәп укучыларын тәрбияләү мәсьәләләренә карый. Татар телендә мәктәп педагогикасы, дидактика, педагогика югары уку йортлары һәм урта һөнәри уку йортлары өчен тәрбия теориясе буенча уку ярдәмлекләре һәм татар әдәбияты дәреслекләре авторы. Ул шулай ук Каюм Насыйри турында да мәкаләләр яза. Аларда К.Насыйриның фәнни-педагогик эшчәнлегенә игътибар юнәлтелә һәм аны берничә этапка бүләргә тәкъдим ителә. Беренче этап 1855–1870 елларны үз эченә ала. Шул чорда К.Насыйриның Руханилар училищесында, соңрак аның дәвамы булган Руханилар семинариясендә укытуы, аның укытучылары белән аралашу аңа рус телен һәм башка фәннәрне киңрәк өйрәнергә ярдәм итүе искәртелә. 1871–1876 еллар К.Насыйриның икенче этап педагогик эшчәнлеген чагылдыра. В.В.*Радловның* Казанга килүе, мәгърифәтченең аңардан татар балаларын русча укытырга мәктәп ачу өчен ризалык соравы, В.В.Радловның мәктәпне оештыруга ярдәм итүе әйтелә. 1876–1902 еллар К.Насыйриның фәнни-педагогик эшчәнлегенең өченче этабын билгели. Бу елларда мәгърифәтче галим төрле юнәлештәге гыйльми эзләнүләр белән шөгыльләнә, дәреслекләр, кулланмалар төзи. Шул ук вакытта мәктәп белән даими бәйләнештә торган, укытучылар белән очрашкан, алар белән үз тәҗрибәсен уртаклашкан, алдынгы педагогик методлар турында матбугатта мәкаләләр бастырып чыгарган, мәктәпләрдә, гимназияләрдә булган, аерым дәресләр биргән. Яңа бистәдә

рус-татар мәктәбендә эшләгән. Ә.Хуҗиәхмәтов К.Насыйриның татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган шәхес булуын, аны фәлсәфи-сәяси мәсьәләләр дә, гыйльми-педагогик, әдәби-эстетик һәм мораль-этик мәсьәләләр дә якыннан кызыксындыруын яза.

«Почёт билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның педагогик эшчәнлегендә тәрбия // Тәрбия дәресләре: Педагогик уку йортлары өчен ярдәмлек. Казан, 1998; Мәгърифәт йолдызлыгы: Укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан, 2002; Татар милли педагогикасы. Казан, 2007 (автордаш); Начало всех начал (Трудовое воспитание в школе). Казань, 1990; Социализация и индивидуализация личности школьника. Казань, 1998.

Әд.: Самаркин Ю.П. Его главнейшая обязанность // Комсомольская правда. 1983. 3 сентября; Юркевич Л.В. Учёный — просветитель // Фән һәм мәктәп = Наука и школа. 1998. № 7.

Ф.С.Гыйниятуллина.

Ц

ЦАРЁВ Сергей Владимирович (10.09.1985, Татарстанның Яшел Үзән шәһәре), рәссам, нәкышьче, график, педагог. ТР һәм РФ Рәссамнәр берлеге әгъзасы (2015).

Казан сәнгать училищесының нәкышь бүлеген (2006), Санкт-Петербург нәкышь, скульптура һәм архитектура академиясенең китап графикасы факультетын (2012) тәмамлый. 2013–2016 елларда — Мәскәү академия сынлы сәнгать институтының Казан филиалында өлкән укытучы, бер үк вакытта, 2013 елдан, Яшел Үзән балалар сәнгать мәктәбендә укыта, 2017 елдан — директоры.

Рәссам пейзаж, портрет жанрларында иҗат итә. Әсәрләре: «Күңел бит — монда» (2016), «Тынычлык урамы» (2022), «Яшьлек» (2023) һ.б. Аның график әсәрләрендә ксилография мөһим урын алып тора. Гравюрада үз фикерен кабатланмас пластик телдә күрсәтә алучы рәссам буларак ачыла.



С.В.Царёв. «Каюм Насыйри». Мурал. А.Җиһаншин белән автордашлыкта. 2022.



С.В.Царёв

График әсәрләре: «Телефон» (2011), «Каюм Насыйри» (2022), «Романов күпере» (2022) һ.б. «Каюм Насыйри» картинасы — мәчет һәм авыл йортлары фонында К.Насыйри бюсты белән график композиция. 2018 елда С.Царёв уеп бизәк төшерүче Альберт Җиһаншин белән берлектә Яшел Үзән шәһәре китапханәсе фасадын бизәп торучы К.Насыйри портретын ясый. Стенага шулай ук мәгърифәтченең татар һәм рус телләрендә: «Китап — бакча, язулар — шул бакчаның гөлләре» дигән мәгънәле сүзләре язылган.

2006 елдан төрле конкурсларда катнаша: «Татарстанның кара алтыны» конкурсы (2013, «Татарстан нефтьчеләре» эше өчен 2 нче урын ала), «Кызыл капка. Агымга каршы» төбәкара академик күргәзмә-конкурсы (2014) һ.б.

Картиналары Санкт-Петербург, Чабаксар, Уфа, Киров, Архангельск һ.б. шәһәрләр дәүләт музейларында, Яшел Үзән шәһәре сәнгать галереясында, Россия, Италия, Бөекбритониядә шәхси коллекцияләрдә саклана.

Ф.Г.Камальтдинова.

Ч

ЧИЖО́ВА Н.М. БАСМАХАНӘСЕ́, Казандагы шәхси басмаханә. 1880 елда ачыла. Беренче хуҗасы — нашир, мөхәррир, драматург һәм прозаик В.М.Ключников. Хуҗалары патша хөкүмәте тарафыннан эзәрлекләнү сәбәпле, 1909 елның апрелендә басмаханә ябыла һәм шул ук елда нәселдән килгән дворян Н.М.Чижова милкенә күчә. 1909–1910 елларда татар телендә гомуми тиражы 140500 данә исәпләнгән 37 исемдәге басма дөнья күрә. Шуларның яртысыннан артыгы «Мәгариф» нәшрияты заказы була, шул исәптән 1909 елда Каюм Насыйриның «Буш вакыт» әсәре биш кисәккә бүленеп бастырыла.

Әд.: Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. Казань, 1974; шул ук. Из истории татарской дореволюционной книги // Здравствуй, книга! Казань, 1989.

И.Х.Хәлиуллин.

ӘЛ-ЧОКРЫ́Й Гарифулла бине Гали (Гарифулла Мөхәммәтгали улы Киеков) (1861–1918), дин эшлеклесе, шагыйрь, публицист, тарихчы; Каюм Насыйри турында истәлек авторы. Аның истәлеге беренче мәртәбә «Шура» журналында (1913) дөнья күрә. Аннан соң әдәбият галиме Фатыйма *Ибраһимова* тарафыннан «Әдәби мирас»ның 3 нче китабында (1996) бастырыла.

Әлеге хатирәләрдә: «1879 елда әткәмне өченче мәртәбә хаҗ сәфәренә паровоз белән Казангача озата килеп, Шыгай мәдрәсәсенә кайта алмый калдым. Казан шәһәрендә булган мәдрәсәләрне әткәй белән йөреп, күреп беткәч, Насыйригa кердек. «Улыңыз ничә яшьтә?» — дигәч, әткәмез: «16 сы тулып 17 гә чыкты», — диде. «Ник Учительский ышкулга бирмәдеңез?» — диде. «Бик сорадылар, ләкин йибәрә алмадык инде», — дигәч: «Мулла итмәкчесездер, ләкин имам булып милләткә хезмәт күстәрмәк мөшкелдер», — диде. «Сезнең шигырьләреңез, әсәрләреңез бик матур, мәгәр бастырырга кирәк иде», — диде», — дип бәян ителә. Гарифулла Казанда биш ел яши, үзлегеннән дә, мәдрәсәләргә йөреп тә гыйлем эсти. Буш вакыты булган саен К.Насыйри белән очрашуын, аның курайда да уйнаганын тыңлавын, мәгърифәтченең 1880 елда И.С.Перов ташбасмаханәсендә басылган «Шәҗәрәи Хөсәения» дип аталган нәсел шәҗәрәсен алып кайтып сатуын ассызыклый. Шулай ук кара: *Истәлекләр*.

Хезм.: Габделкаюм ән-Насыйри // Шура. 1913. № 5; Чокрый Гарифулла ибн Гали // Әдәби мирас. Казан, 1996. 3 нче кит.

Ф.С.Гыйниятуллина.

Ш

ШАЙДА́ЕВА (Зәйнетдинова) Лилия Наил кызы (23.04.1976, Татарстанның Куйбышев (хәзер Спас) районы Ямбакты авылы), филолог, филология фәннәре кандидаты (2010).

Түбән Кама шәһәренең 1 нче татар гимназиясен (1993), Казан университетының татар филологиясе, тарихы һәм шәрекъ телләре факультетын (1998) тәмамлый. 1996 елдан — Казан шәһәренең 71 нче гимназиясендә гарәп теле, 1998 елдан татар теле һәм әдәбияты укыта. 2005 елдан — Казанның 109 нчы балалар бакчасында татар теленә өйрәтүче тәрбияче. Бер үк вакытта, 1998–2001 елларда, ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспирантурасында укый. 2010 елда К.Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»ы: проблематикасы һәм сәнгати үзенчәлекләре» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Әлеге хезмәттә «Фәвакиһел-җөләса» китабында чагылыш тапкан мәгърифәтчелек идеяләренә, гуманистик карашларга, анда күтәрелгән төрле проблемаларга тукталып үтелә, җыентыкның төзелеше һәм эчтәлеге җентекләп тикшерелә.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы һәм «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

Хезм.: Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» әсәрендә әхлак һәм гаилә мөнәсәбәтләре мәсьәләсе // Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре. Казан, 2000; Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» җыентыгында әфләтуни (платонический) мәхәббәт турында хикәяләр // Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре. Казан, 2000; Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-жөләса фил-әдәбият» җыентыгында хикәят-новеллалар // Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре. Казан, 2002; Каюм Насыйрины «Фәвакиһел-җөләса» әсәрендә күтәрелгән проблемалар // Фән һәм тел. 2008. № 3; Идейно-эстетические и структурные особенности «Фаваких аль-джуласа» Каюма Насыри // Вестник Чувашского университета. Гуманитарные науки. Чебоксары, 2009. №4.



Л.Н.Шайдаева

Әд.: Сиражи Э. «Француженка» Лилия // Мәдәни җомга. 2019. 10 ноябрь.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ШАКИРЖА́НОВ Рәшит Әгъләулы (07.06.1949, Татарстанның Биектау районы Ямаширмә авылы – 22.11.2021, Казан), корылма механикасы, педагогика, филология фәннәре галиме, журналист, техник фәннәр кандидаты (1990), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2009), ТРның атказанган югары белем бирү хезмәткәре (2015). ТР Дәү-

ләт бүләге лауреаты (2009). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2013).



Р.Ә.Шакиржанов

Казан университетының механика-математика факультетын тәмамлаганнан соң (1975), Казан архитектура-төзелеш институтында: 1993 елдан — корылма механикасы кафедрасы доценты, 2008 елдан — кафедра профессоры, 2002 елдан — студентларны татар телендә укыту буенча методик кабинет мөдире. Бер үк вакытта татар телендә чыккан «Фән һәм тел» журналының баш мөхәррире (1997–2015) була.

Хезмәтләре корылмалар механикасына, милли мәгариф системасын төзү, педагогика, татар телен саклау һәм үстерү, татар телендә фәнни-техник терминологик сүзлекләр төзүгә, журналистика һәм төбәк тарихы мәсьәләләренә карый. Ул татар телендә югары белем бирүне оештыру концепциясен, корылма механикасын татар телендә укытуның методик курсын тәэмин итә; төзелеш, нефть сәнәгате буенча русча-татарча сүзлекләр төзи, югары уку йортлары өчен корылма механикасы (2008), физика (2018) дәреслекләре, уку кулланмалары чыгара. Дәүләт бүләге Татарстан Республикасының белем бирү системасында татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кертүне фәнни, укыту-методик һәм мәгълүмати-программалаштыру буенча тәэмин иткәне өчен бирелә. Каюм Насыйри исемендәге бүләккә «Югары уку йортларында татар телендә укытуның теоретик һәм гамәли нигезләре» хезмәте өчен лаек була. Р.Ә.Шакиржановның Н.К.*Туктамышев* һәм А.З.*Камалов* белән авторлашлыкта язылган әлеге хезмәтендә татар телендә белем бирүне концептуаль һәм фәнни-методик яктан үстерү, татар телендә укытуны мәгълүмати һәм терминологик яктан тәэмин итү буенча күп еллар дәвамында алып барылган эш нәтиҗәләре яктыртыла. «Татар теленең танып белү алгоритмын фән һәм җәмгыятьне үстерү өчен куллану» хезмәтендә (2002) галим: «...ана телендә югары белем бирү системасы булганда гына, татар теле башка телләр белән конкуренциядә оттырмыйча сакланып калачак, үсәчәк һәм димәк, татар халкы да яшәячәк», — дип яза.

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы, «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә.

Хезм.: Ямаширмә мәктәбе — мәгърифәт чишмәсе: татар мәгарифенең үсеш юллары. Казан, 2005; Корылма механикасы: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан, 2008; Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. Казан, 2011, Төзү материаллары: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан, 2012 (автордаш); Физика: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан, 2018 (автордаш); Туган телне саклау юлында. Казан, 2021, Русско-татарский политехнический словарь. Казан, 2016 (автордаш).

Әд.: Исламов Ф.Ф. Ямаширмәнең мәгърифәт чишмәләре // Мәдәни җомга. 2007. 19 гыйнвар; Камалов А. Рәшит Шакиржановка 60 яшь // Фән һәм тел. 2009. № 2; Татар педагогик фикере антологиясе. 2 т. Казан, 2016.

Ф.Г.Камальтдинова.

«ШАТЛЫ́К», Чаллы шәһәрендәге 1 нче балалар бакчасы; ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының муниципаль автономияле мәктәпкәчә белем бирү йорты, баланың аң-белемен

үстерү үзәге. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2014). 1992 елда ачыла. 295 бала тәрбияләнә, 31 педагог эшли (2024).

Эшчәнлегендә төп урынны милли тәрбия алып тора, ул Идел буе халыкларының гореф-гадәтләре һәм йолалары нигезендә, тарихи-мәдәни, милли, мәгърифәт, тел, әдәбият-сәнгать казанышларын кулланып, ике телдә алып барыла. Балалар Чаллы үзәк китапханәсенә, шәһәр тарихы музеена, «Чишмә» халыклар дуслыгы йортына экскурсияләргә йөриләр. Өстәмә белем бирү чаралары, төрле бәйгеләр үткәрелә. Татар теле тәрбиячесе Г.М.Гомәрова (Гумирова) төзегән «Дуслык белән көчле без!» методик кулланмасы балалар бакчалары эшчәнлегендә тәрбиячеләр, педагогик коллективлар өчен ярдәмлек буларак кулланыла. Балалар бакчасында К.Насыйри иҗаты һәм эшчәнлеге турында гамәли чаралар үткәрелеп, күргәзмә материал бирелеп тора. Бакча балалары белән берлектә ел саен шәһәр үзәк китапханәсендә февраль аенда К.Насыйрины искә алу кичәсе уздырыла.



Чаллы шәһәренең «Шатлык» балалар бакчасы – баланың аң-белемен үстерү үзәге.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк татар мәгарифен үстерүдәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен бирелә.

И.Х.Хәлиуллин.

ШӘҖӘРӘ (гарәп теленнән — агач), нәсел агачы, татар, башкорт һәм башка төрки халыкларда генеалогик язма. Язмача һәм телдән тапшырылу рәвешендә яшәп килә. Шәҗәрәнең төп эчтәлеген теге яки бу нәселнең борынгы бабаларыннан алып иң соңгы варисларына кадәрге вәкилләренең исемлеге тәшкил итә; кайвакыт ул искә алынган затлар тормышыннан мәгълүматлар белән тулыландырыла.

Шәҗәрә — үткәннәр турындагы белемнәрнең иң борынгы формаларыннан берсе. Ул ыруглык җәмгыяте чорында формалаша. Тарихи белемнәрнең башка формалары үсеше барышында икенчел урынны били. Ыруглык мөнәсәбәтләре сакланып калган халыкларда, мәсәлән, күчмә халыкларда, шәҗәрәләр нык саклана. Аларда «гомумәтник» («гомуммилли») тарих вазифаларын башкарган гомумыруг, гомумкабилә шәҗәрәләре өстенлек итә. Утрак тормышлы халыкларда шәҗәрә аерым, ягъни гаилә-фамилия нәсел агачы рәвешендә була; община шәҗәрә төре дә очрый, алар бер яки берничә торак пунктта яшәүче община кешеләре турында генеалогик мәгълүматларны колачлый. Татар шәҗәрәсенең иң элгәреге үрнәкләре 14–16 йөзләр эпитафияләрендә, 16–18 йөзгә караган тарихи хезмәтләрдә («Җамигъ әт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» һ.б.) чагылыш таба. Алар аерым ырулар һәм фамилияләрнең социаль чыгышы, татар халкы күченешенең сәбәпләре һәм юнәлешләре, торак пунктлар тарихы буенча мәгълүматларны, татар халкының килеп чыгышы буенча материалларны (тамырлары болгарлардан, Алтын Урдадан, нугайлардан һ.б.дан килүе турындагы мәгълүматларны) үз эченә ала.

Каюм Насыйриның шәҗәрәсе беренче мәртәбә ташбасма ысулы белән *Перов И.С. ташбасмаханәсендә* 1880



Каюм Насыйри энесе Габделкави белән төзегән нәсел шәҗәрәсе. Литография. И.С.Перов ташбасмаханәсе, 1880.

елда 200 нөсхәдә бастырыла. Басманың үзендә күрсәтелгәнчә, галим аны энесе Габделкави белән берлектә төзегән. Алар фикеренчә, ир-ат ягын дәвам итүчеләр сары төстәге яфрак рәвешендә, ә хатын-кыз ягы кызыл төс белән күрсәтелергә тиеш була. Ләкин, чынлыкта, эш киресенчә башкарылган. Ташбасма ысулы белән нәшер ителгән икенче шәҗәрә ТР Фәннәр



Каюм Насыйри энесе Габделкави белән төзегән нәсел шәҗәрәсе. Литография. И.С.Перов ташбасмаханәсе, 1880.

академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының *Язма мирас үзәгендә* саклана. Ул К.Насыйриның әтисе ягыннан дәү әнисеннән башлана. Анда галимнең абзасы Габделхәй Насыйри һәм ике буын туганнары теркәлгән.

К.Насыйриның Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъ-

язмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә сакланучы документлары арасында аның туганнарының аерым шәҗәрәләре дә бар, ләкин ачыкланганча, анда галим нәселдәшләренең туу һәм вафат булулары турындагы фактлар бик аз күрсәтелгән.

Әд.: Әхмәтҗанов М.И. Татар шәҗәрәләре. Казан, 2011; Исламов Р., Хуҗиева Э. Ачыклыйсы сәхифәләр һаман кала әле... // Кызыл таң. 2024. 6 декабрь; Ахметзянов М. Татарские шеджере. Исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах по спискам XIX–XX вв. Казань, 1991.

Ф.Г.Кәлимуллина.

ШӘЙДУ́ЛЛИН Рафаил Вәли улы (30.03.1960, Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районы Лабит авылы), тарихчы, энциклопедист, педагог, тарих фәннәре докторы (2004), профессор (2007), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2010). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). «Каюм Насыйри» персональ энциклопедиясенең фәнни концепциясен эшләүче, авторлар коллективы җитәкчесе һәм җаваплы редакторы.

Казан университетының тарих факультетын (1987), шунда ук аспирантураны (1990) тәмамлый. 1990–1992 елларда СССР Фәннәр академиясе (1992 елдан — Россия Фәннәр академиясе) Казан Гыйльми үзәгенең Тел, әдәбият һәм тарих институты, ТР Фәннәр академиясенең Татар Совет Энциклопедиясе бүлегендә гыйльми хезмәткәр вазифаларын башкара. 1993–1994 елларда — ТР Фәннәр академиясе Президиумы карамагындагы Татар энциклопедиясе институтында тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге мөдире. 1994 елдан — ТР Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында: тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге мөдире (2014 елның апреленә кадәр), 2011 елдан — директорның беренче урынбасары, 2015 елдан — Энциклопедистика үзәге мөдире. Бер үк вакытта, 1991 елдан, Казан федераль университетында укыта: 1999 елдан — кафедра доценты, 2005 елдан — кафедра профессоры.



Р.В.Шәйдуллин

Хезмәтләре Россия һәм Татарстанның социаль-икътисади, иҗтимагый-сәяси һәм этномәдәни тарихына, татар крестьяннары, татар мәгарифе һәм энциклопедистикасы тарихын өйрәнүгә карый. Соңгы ун елда аның турыдан-туры җитәкчелегендә «Татарстан дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең үзәк органнары» (2010, 2017), «Татарстан Республикасының юкка чыккан торак пунктлары» (2016), «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль символлары» (2017), «Казакъстан татарлары» (2016, 2018), «Татарстанга — 100 ел» (2019), «Татарстанның сәяси эшлеклеләре (1920–2020)» (2020), «Казан: хакимият һәм үзидарә органнары» (2021, 1 нче кит.); «Казан: тарихи районнар, бистәләр, урамнар һәм парклар» (2021, 1 нче кит.), «Татарстан халыкларының үзешчән сәнгать коллективлары» (2022, 1 нче кит.), «Татарстан халыклары үзешчән иҗатының традицион бәйрәмнәре һәм фестивальләре» (2024) кебек энциклопедияләр, фәнни-белешмә басмалар эшләнде һәм дөнья күрде.

Р.Шәйдуллин «Татар энциклопедия сүзлеге», алты томлы «Татар энциклопедиясе», «Казакъстан татарлары», «Татарстан халыклары», «Каюм Насыйри» һәм башка энциклопедик

басмаларның фәнни концепциясен һәм фәнни-методик нигезләрен эшләүгә зур өлеш кертә. К.Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында аның җитәкчелегендәге авторлар коллективы мәгърифәтче галим турында татар халкы, Татарстан тарихы һәм мәдәниятендә беренче персональ энциклопедия төзи. К.Насыйриның күпкырлы фәнни-гамәли эшчәнлеген яктырткан мәкаләләр белән чыгыш ясый, шул рәвешчә галимнең татар җәмгыятендә фәнни һәм гамәли белемнәрне популярлаштырудагы зур өлешен, аның фәнни һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегенең киң масштабын күрсәтә.

ТРның Мактау грамотасы, «Фидакарь хезмәт өчен», «ТАССР төзелүгә 100 ел» медальләре белән бүләкләнә.

Хезм.: Татарның гажәеп шәхесе // Мәгариф. Казан, 2024. № 8 (1116); Каюм Насыйри: татар мәгърифәтчесе һәм галим-энциклопедист (200 еллык юбилее уңаеннан) // Языки и культуры народов Татарстана. Казань, 2024. Ч. 1–2; Крестьянство Татарстана: экономический и общественно-политический аспекты (1920–1929 гг.). Казань, 2004; Мусульманское религиозное образование в деревне Татарстана (1917–1929 гг.). Казань, 2004 (автордаш); Из истории национального образования нерусских народов Поволжья и Приуралья. Казань, 2016 (автордаш); Казань — город национального согласия в историческом дискурсе // Города Среднего Поволжья: история и современность (к 440-летию города Йошкар-Олы). Йошкар-Ола, 2024.

Әд.: Рафаил Шәйдуллин // Татар педагогия фәннәре антологиясе: 2 томда. 2 т. (XX гасыр – XXI гасыр башы). Казан. 2016; Шайдуллин Рафаиль Валеевич / Татарская энциклопедия. Казань, 2014. Т.6; Хамидуллин Б.Л. Ведущий энциклопедист Татарстана Шайдуллин Рафаиль Валеевич // Вопросы энциклопедистики. Уфа, 2020. № 2 (4).

ШӘЙМӘРДА́НОВ Шәйгәрдән Шәймәрдән улы (1890 елның сентябре, Уфа губернасының Минзәлә өязе (хәзер Татарстанның Актаныш районы) Иске Байсар авылы — 1940 елның гыйнвары, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе.

Тышкы сәүдә академиясен тәмамлый (1933). 1911 елдан хәрби хезмәттә, Беренче бөтендөнья һәм Граждан нар сугышларында катнаша. 1918 елдан административ-хуҗалык һәм партия эшендә: Минзәлә кантоны советы башкарма комитеты рәисе урынбасары (1918–1921), шул ук советның башкарма комитеты рәисе (1921–1924), бер үк вакытта, 1921 елдан, Минзәлә кантоны хәрби комиссары. 1924 елдан — ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе урынбасары, 1925 елдан — Үзәк Башкарма Комитеты рәисе. 1927–1928 елларда — ТАССРның Халык Комиссарлары Советы рәисе. 1928 елдан — Мәскәүдә: ВКП(б) Үзәк Комитетының җаваплы инструкторы (1928–1930), РСФСР Финанслар халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы, «Совафганторг» рәисе урынбасары, СССРның Тува Халык Республикасындагы сәүдә вәкиле (1935–1937). 1937 елдан Тышкы сәүдә халык комиссариатында эшли. 1938–1939 елларда — Бөтенсоюз «Союзпушнина» берләшмәсе башлыгы урынбасары. Милли кадрлар әзерләүгә һәм республикада эш башкару процессын татар теленә күчерүгә зур өлеш кертә. ТАССРның беренче Конституциясе проектын эшләүдә катнаша (1926). Сәяси репрессияләр корбаны, үлгәннән соң аклана.

Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан Казанда уздырылган

җыелышта котлау хаты язучы буларак мәгълүм. Әлеге хат «Безнең юл» журналында (1925) басыла. Анда: «...Йөз еллыгы уңае белән бәйрәм ителгән Каюм бабабыз үзенең гыйльми-әдәби хезмәткәрләре белән татар тарихының менә шундый кадерле эшчеләренең берсе, бәлки, беренчесе. Шуңа күрә Татарстан җөмһүрияте хөкүмәте ул өлкән бабаның туганына йөз ел тулган көнне олылап үткәрүне тиешле санады һәм башка берничә төрле сагынмалык-ядкяр эшләү белән бергә аның әсәрләреннән, һич булмаса, кайберләрен бастыру, аның тормышы, хезмәте турында тулы материал, мәгълүмат бирерлек мәҗмуга чыгару чаралары күрәчәк...», — дип язылган. Тулырак кара: *Гыйльми үзәк*.



Ш.Ш.Шәймәрдәнов



З.Р.Шәйхелисламов

Хезм.: Каюм бабага йөз ел // Безнең юл. 1925. №5 (автордаш).

Әд.: Имамов В. Хөкүмәт башлыгы Шәйгәрдән Шәймәрдәнов // Актанышым — ак илем. Казан, 2010; Касимов Г. Шаймарданов Шайгардан Шаймарданович // Борцы за счастье народное. Казань, 1963. Кн. 2.

Ф.С.Гыйниятуллина, Ф.Г.Миңнеханов.

ШӘЙХЕЛИСЛА́МОВ Заһир Рәхмәтулла улы (11.04.1953, Чиләбе шәһәре), әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты (1999).

Казан университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, 1978–1981 елларда Татарстанның Сарман районы Каташ-Каран сигезьеллык мәктәбендә укыта. 1981–1985 елларда ТАССР Мәдәният министрлыгының Республика фәнни-методик үзәгендә репертуар бүлеге мөхәррире вазифасын башкара. 1985 елдан — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1993–1997 елларда ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1997–2016 елларда Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында: өлкән фәнни хезмәткәр, кулъязмалар һәм текстология бүлеге (2001–2007), аспирантура бүлеге (2007–2011) мөдире булып эшли. Институт тарафыннан нәшер ителгән «Әдәби мирасның яңа катламнары» (1990), «Әдәбият чыганаклары һәм текстология» (1992), «Әдәбият чыганакларын барлаганда» (1994) хезмәтләрен, Г.Тукай әсәрләренең 6 томлы академик басмасының 3 нче томын (2014), «Нурмөхәммәт Хисамов: галим, шагыйрь, шәхес» (2007) басмасын төзүче. «Нил Юзеев — шигъри җанлы акыл иясе» (2000) басмасын әзерләүдә, Г.Тукай «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче томын (2006), шагыйрь әсәрләренең 6 томлы академик басмасының 2 нче томын (2011) төзүдә катнаша. 2002 елда «Аңлыем дип шагыйрь җанын... (Ә.Фәйзи иҗатында Тукай темасы)» монографиясен бастырып чыгара.

Каюм Насыйрины үз вакытында халкыбыз арасында популяр булган «Хәвасе нәбатат дәваәят, ягъни тыйбта мөсәгъмәл нәбатат вә үләннәрнең хасыятене бәян кылур» хезмәтен, хәзерге укучыга аңлаешлы итеп гамәлдәге татар хәрефләрендә башкарып, аны кереш өлеш һәм бай аңлатмалар белән тулыландырып, «Шифалы үлән-

нәр» исемендә нәшер итә (1999). Анда үсемлекләрне татарча, гарәпчә-фарсыча атамалары белән берәттән русча яңгырашлары да бирелү фитонимия өлкәсендә шөгыльләнүчеләр өчен мәгълүмати чыганак булып тора. Шулай ук кулланылыштан төшеп калган үлчәү берәмлекләре атамаларының да шул вакыттагы исемнәре турында белешмә урнаштырылган.

Хезм.: Шәйхелисламов З. Аңлыем дип шагыйрь җанын... Казан, 2001.

Әд.: Бәшир Ф. Әдип рухын яд итеп // Мәдәни җомга. 2003. 11 июнь; Исламов Р. Гыйльми эзләнүләр юлында // Шәһри Казан. 2033. 11 апрель; шул ук. Шәйхелисламов // Габдулла Тукай. Энциклопедия. Казан, 2016; Шәйхелисламов // Сарман районы энциклопедиясе. Яр Чаллы, 2000.

Р.Ф.Исламов.



Н.Нәкъкаш. «Каюм Насыйри». Шәмаил-плакат. Катнаш техника. 2023.

ШӘМАЙ́Л (гарәп теленнән — сыйфат, дәрәҗә), каллиграфия ысулында Коръән текстлары язылган, күренешләр (изге урыннар, мәчетләр һ.б.) һәм сюжетлы символлар төшерелгән дивар панносы. Ул — халык аңында Аллаһка ышану, Коръәннән китерелгән сүзләрне олылау билгесе.

Борынгыдан килгән шәмаил текстлары татар халкының рухи мирасының аерылгысыз бер өлеше булып тора. Бу мирас татар әдәбияты традицияләре, дини риваятьләр һәм халык ышанулары белән бәйле. 1920 елларда шәмаил сәнгате юкка чыкса да, 1970 елларда Бакый *Урманче* ижатында ул яңара, 1980 еллар ахырыннан киң колач ала. Бу юнәлештә Фирдәвес Гыйрфанов, Әлфия Исхакова, Раиф Мәрданов, Нәҗип Нәкъкаш (Исмәгыйлев), Рамил Насыйбуллов, Владимир Попов, Рушан Шәмсутов, Чулпан Шәрифуллина һ.б. әйдәп баралар. Алар арасында рәссам-хаттат Нәҗип Нәкъкаш (Исмәгыйлев) аерым урын били. Күренекле татар мәдәният эшлеклеләренең аның тарафыннан ижат ителгән тугралары да урнаштырылган шәмаилләр киң таныла. Аерым алганда, милләт мәнфәгатен кайгыртуны үзенең яшәү рәвеше иткән мәгърифәтче галим Каюм Насыйригa багышланган шәмаил-плакатында (2023): өстә — К.Насыйриның тугласы, уңнан сулга, астан өскә таба «Габделкаюм Габден-



Н.Нәкъкаш. «Ният кылдым гыйлем өйрәнергә». Катнаш техника. 2005.

насыйр угълы», — дип, тугра астында гүзәл шәкелдә — «Без — татарлар, телебез — татар теле; мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул» дигән сүзләр китерелгән. Бу хезмәтне автор берничә вариантта эшли. Н.Нәкъкашның мәгърифәтчегә багышланган тагын бер «Ният кылдым гыйлем өйрәнергә» дигән шәмаиле Татарстанның Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылында К.Насыйри исемендәге *Архитектура-этнография комплексында* саклана. Шәмаил горизонталь форматта, фирүзә фонда алтын язулы, тексты татар бизәкләре белән уратып алынган. Шәмаилдә: «Иләһи, ният кылдым гыйлем үгрәнмәккә, белмәгәнемне белмәк өчен, вә шәригатьне тергезмәк өчен, дине исламны бакый кылмак өчен» дигән сүзләр язылган.

Әд.: Гилемшин Ф.Ф. Особенности текстового содержания арабографических шамаилей казанских татар // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2017. №8 (74). Ч. 2; Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. Казань, 2003.

Ф.Г.Камальтдинова.

ШӘМСЕТДИ́НОВ Рушан Галәф (Галәветдин) улы (25.11.1946, Казан), график, каллиграф, нәкышьче, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1997), ТРның халык рәссамы (2011), ТР һәм РФ Рәссамнар берлеге әгъзасы (1994, 2001).

Казан сынлы сәнгать училищесын (1966), Мәскәү полиграфия институтын (1981) тәмамлый. 1963 елдан «Чаян», «Азат хатын», «Сөембикә», «Ялкын», «Салават күпере», «Мирас» (1991–1993 елларда — бизәлеш мөхәррире) журналлары, «Социалистик Татарстан», «Комсомолец Татарии», «Советская Татария», «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталары белән хезмәттәшлек итә. 1970 елдан — «Теплоконтроль» заводының проект-



Р.Г.Шәмсетдинов

лау бюросында, 1975–1978 елларда — Казан сувенирлар фабрикасында рәссам. 1968 елдан — Татарстан китап нәшриятында рәссам, штаттан тыш рәссам (1980 елдан), бизәлеш редакциясе мөдире (1993–2007).


Р.Шәмсетдиновның әнисе ягыннан Сәгыйтовлар нәселе Каюм Насыйрилар нәселенә барып тоташа. Рәссамның ерак бабасы Сәгыйд бине Әхмәд *әш-Шырдани* белән Каюм Насыйриның әнисе бертуганнар. Әлеге нәселдәге кардәшлек җепләре Р.Г.Шәмсетдинов тарафыннан төзелгән шәҗәрәдә туганлык бәйләнешләрендә чагыла.

Китап графикасы өлкәсендә әйдәп баручыларның берсе, 500 гә якын китап бизи, шул исәптән: «Идегәй» (1994); «Нуры содур» (Мөхәммәдъяр; 1997); «Кыйссаи Йосыф» (Кол Гали; 1999); «Шаһнамә» (Әбелкасыйм Фирдәүси; 2003); «Могҗизанамә» (Мөхәммәдәмин; 2005); «Сайланма әсәрләр» (Разил Вәлиев; 2006); «Сәйфелмөлек» (Мәҗлиси; 2007); «Сайланма әсәрләр» (Уильям Шекспир; 2007). «Биш баһадир» (2001), «Әсирлектән кайткан әкиятләр» (2002), «Алтын сандык» (2003); балалар өчен «Татар тарихы» альбомнар сериясенә (1–6 китаплар, 2002–2008) иллюстрацияләр ясый.

Аның иҗаты шулай ук татар халык сәнгате традицияләренә, Шәрекъ миниатюраларына хас бизәклелек, яссылык, шартлылык, символлык, полихромия ысулларын файдалануга нигезләнә. Станлы графикада (темпера, гуашь, акварель, тушь) һәм станлы нәкышьтә тарихи шәхесләр образларының автор күзаллавындагы портретларын гәүдәләндерә: «Идел

буе Болгары солтаннары» (1990–1994), «Алтын Урда ханнары» (1991–1999), «Казан ханнары» (1992–1998), «Татар халкының каһарман бабалары» (1991–1994), «Борынгы шагыйрьләр» (1990–1996); замандашлары — ТР Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов (1998), язучылар Аяз Гыйләҗев, Рабит Батулла (икесе дә — 1997), шагыйрьләр Мөдәррис Әгъләм (1997), Роберт Миңнуллин (2010), композиторлар Рөстәм Яхин (1997), Сара Садыйкова (2006) һ.б.ның портретларын ясый. Станлы сәнгатьтә тематик картиналар, портрет, пейзаж жанрында эшли, шулар арасында: «Алтын Урда. Хан ау вакытында» (2002), «Сөембикә һәм Үтәмешгәрәй хан. Сафагәрәй төрбәсе янында» (2003), «16 йөздә Казан. Ак барс» (2007), «Татарстан. Ак барс» (2008), «Г.Тукай» триптихы (2010–2011). ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленә костюм эскизлары, Илһам Байтирәкнең «Сәрвиназ» балетына декорация һәм костюм эскизлары иҗат итә (барысы да — 2004–2005). Р.Шәмсетдинов эскизлары буенча Казан метрополитенының «Тукай мәйданы» станциясендә мозаикадан Г.Тукай әсәрләренә 19 дивар панносы эшләнә.

Р.Шәмсетдинов — танылган каллиграф: «Аллаһы исеме» (1992), «Икмәкнең кадерен бел» (1998), «Галәм. Аллаһы көрсие» (2006), «Бисмилла» (2006), «Пәйгамбәрләр» (2009), «Ислам пәйгамбәрләре»



Р.Г.Шәмсетдиновның әнисе ягыннан шәҗәрәсе.

темасына 27 дивар панно-шәмаиллəре.

Китап рәссамнарының 1 нче (1981), «Татарстан китабы сәнгате», «Яңа графика» күргəзмəлəрендə (икесе дə — 2007), «Шəмаилләр конкурсы»нда (2009); Шəмаилләр (Мəскəү, 2004), «Габдулла Тукай — 125 ел» (Мəскəү, Санкт-Петербург, 2010); халыкара — «Шүрəле һəм мин» (Казан, Мəскəү, 2011; Уфа, 2012), ТЮРКСОЙ (Төркия, Әнкара, 2012) күргəзмəлəрендə катнаша.

Әсəрлəре ТР Дəүлəт сынлы сəнгать музеенда, Чаллы картиналар галереясында, Матбугат академиясендə (Мəскəү), Россия фән һəм мəдəният үзəгендə (Прага шəһəре, Чехия), Россия һəм чит илләрдəге (Франция, АКШ, Төркия, Тунис, Монголия, Эстония һ.б.) шəхси тупланмаларда саклана.

«Казан сувениры» конкурсы (1975), Бөтенроссия сəяси плакатлар конкурсы 1 нче (Мəскəү, 1981), Кол Гали исемендəге халыкара (Казан, 2000) бүләкләр лауреаты; «Гарəп каллиграфиясе» бөтенроссия конкурсы җиңүчесе.

«Казанның 1000 еллыгы истəлегенə» һ.б. медальлəр белəн бүләкләнə.

Əд.: Вəлиева-Сөләйманова Г.Ф. Шəмсетдинов Р.Г. // Татар энциклопедиясе. Казан, 2021. Т. 6. 2 кис.: Ш–Я; Хəлиуллин И.Х. Игелекле талант (Рəссам Рушан Шəмсетдиновка — 50 яшь) // Казан утлары. 1996. №11; Миннебаев К. Вдохновлённый историей народа // Казань. 1995. №9/10; Шамсутдинов. Р.Г. В мире истории — Тарих дөньясында — In the world of history: Графика. Живопись. Прикладное искусство: Альбом. Казань, 2002; Хамидуллин Б. Любовь. Талант. Мастерство // Идель, 2002. №2; Маликова А. Рушан Шамсутдинов: Цвет несёт настроение // ЭТНОсфера. 2010. №11.

Ф.Г.Камальтдинова.

ШƏМСЕТДИ́НОВА Рəсимə Равил кызы (15.11.1954, Татарстанның Биектау районы Мүлмə авылы), филолог, педагог, филология фəннəре кандидаты (2000), ТРның атказанган мəктəп укытучысы (2003), РФнең атказанган югары мəктəп хезмəткəре (2011). ТР Мəгариф һəм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендəге бүлəге лауреаты (2008).

Казан университетын тəмамлаганнан соң (1976), Казан педагогия училищесында укыта. 1980 елдан СССР Фəннəр академиясе Казан филиалы Тел, əдəбият һəм тарих институтының тел секторында өлкəн лаборант, 1984 елдан кече фəнни хезмəткəр булып эшли; бер үк вакытта, 1982–1986 елларда, Казан консерваториясендə укыта. 1991 елдан — Казан университетының татар теле, шулай ук чит телле аудитория өчен татар теле кафедралары ассистенты, 1992 елдан – чит телле аудитория өчен татар теле кафедрасы өлкəн укытучысы, 2001 елдан — доценты, 2007 елдан — гамəли тел белеме һəм тəрҗемə белеме кафедрасы доценты, бер үк вакытта, 2005 елдан, ТРның Мəгариф һəм фән министрлыгы каршындагы Мəгарифне үстерү институтында (2016 елдан татар теле һəм əдəбияты кафедрасы мөдире), университетның Югары журналистика мəктəбендə татар журналистикасы кафедрасы доценты. ТРның Министрлар Кабинеты каршындагы Терминология комиссиясе əгъзасы (2000–2008).

Хезмəтлəре татар лексикологиясе һəм терминологиясенə (шул исəптəн, татар телендə медицина терминологиясе мəсьəлəсен өйрəнүгə), текстологиягə карый. Ул сүзлекләр, дəреслекләр, уку-укыту һəм методик ярдəмлекләр, уку-укыту программалары авторы. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы

ТР Законын гамәлгә ашыруга зур өлеш кертә.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.



Р.Р.Шәмсетдинова

Хезм.: К. Насыйриның татар анатомия-физиология терминологиясен эшләүдәге роле // Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультеты укытучыларының фәнни язмалары (2002). Казан, 2002; Каюм Насыйри хезмәтләрендә химик атамалар // Мәгариф. 2006. № 3; Татар теле: 2 нче сыйныф: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). Казан, 2013 (автордаш); Татар теле. 3 нче сыйныф: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). Казан, 2014 (автордаш); Әлифба: туган телдә (татар телендә) башлангыч гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен дәреслек: 1 нче сыйныф. Казан, 2016 (автордаш); Русско-татарский словарь медицинских терминов. Казань, 2004; Краткий русско-татарско-английский толковый словарь медицинских терминов. Казань, 2009 (автордаш).

Ф.С.Гыйниятуллина.

ШӘРӘФЕТДИ́НОВ Вил Ширияздан улы (28.04.1933, Татарстанның Алексеевск районы Юеш Көрнәле авылы), рәссам, педагог. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2004).

Казан сәнгать училищесын (1963), Чабаксар педагогия институтын тәмамлый. 1956–1958 елларда Казанның Горбунов исемендәге Моторлар төзү берләшмәсендә эшли. 1963 елдан Яшел Үзән шәһәренең сәнгать мәктәбендә. Балаларны рәсем, скульптура, нәкышь серләренә өйрәтә. 1993 елдан — Яшел Үзәннең 5 нче татар гимназиясендә рәсем, музыка укытучысы. Нәкышь һәм курайда уйнау түгәрәкләре алып бара.

Каюм Насыйри, Пётр Гаврилов, Әхмәтхан Солтанов, Бари Шәвәлиев, Идрис Туктар, Николай Островский, Афзал Шамов бюстлары, Мирхәйдәр Фәйзи, Салих Сәйдәшев, Һади Такташ, Илдар Ханов портретлары авторы. Беренчеләрдән булып, К.Насыйри бюстын эшли. Бронзадан ясалган әлеге бюст 1967 елда галимнең туган авылы *Кече Шырданда* куела. 1997 елда аның тарафыннан иҗат ителгән Каюм Насыйри бюсты Яшел Үзән районы Олы Шырдан авылы мәктәбендә саклана. Шулай ук В.Шәрәфетдинов 50 дән артык музыка уен коралы ясый.



В.Ш.Шәрәфетдинов. «Каюм Насыйри». Гипс. 1967.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Ф.Г.Камальтдинова.

ШӘРИФУ́ЛЛИНА Эльмира Мөхәммәт кызы (04.06.1947, Татарстанның Сарман (хәзерге Мәслим) районы Симәк авылы), педагог, язучы, журналист, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1993), Язучылар берлеге әгъзасы (1985). Сажидә Сөләйманова (2014), Абдулла Алиш (2021) исемендәге әдәби бүләкләр иясе. ТР

Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри бүләге (2021) лауреаты.

Минзәлә педагогия училищесын (1966), Казан университетының тарих-филология факультетын (1978) тәмамлый. 1966–1967 елларда — Мамадыш шәһәрендә пионерлар йорты директоры, бер үк вакытта Мамадышның 2 нче мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы. 1968 елда — «Ялкын» журналында кече мөхәррир, пионерия бүлеге мөхәррире. 1968 елдан — Яшел Үзән шәһәренең 6 нчы һәм 3 нче мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 1971 елдан — ТР телевидениесендә хатлар бүлеге мөхәррире, 1974 елдан — «Ялкын» журналында бүлек мөдире, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй»), «Мәгариф» газеталарында әдәби хезмәткәр. 1993–2004 елларда — Казан педагогия көллиятендә укытучы-методист.

Иҗатының төп юнәлеше — лирика һәм балалар өчен шигырьләр. «Яңгыр җиле» (1984), «Зәңгәр эңгер» (1991), «Таң чыгы» (1998), «Уйлы еллар» (2003), «Тамды яшем» (2012) шигырь җыентыклары, «Мәхәббәтнең җиде төсе» хикәяләр һәм повестьлар җыентыгы (2007); балалар өчен «Безнең зоопарк» (1976, 4 нче басма, 1999), «Җитәкләшеп җил белән» (1990), «Ничек, нинди, ни төсле?» (2000) шигырь җыентыклары, «Иң матур әни» (1999), «Алтын балык» (2000), «Баллы балачак» (2009) әкиятләре авторы. «Асрамага бала бирәм» (1994), «Казаныңа ни салсаң...» (2005), «Бала күңеле ак кәгазь»(2015) җыентыклары мәгариф, педагогика тарихына, халык мәгарифенең танылган эшлеклеләренә багышлана.

«Каюм коесы» (2018) китабы татар халкының күренекле шәхесләре турындагы 6 поэманы үз эченә ала.



Э.М.Шәрифуллина

«Каюм коесы» поэмасы — мәгърифәтче галим К.Насыйригa багышланган беренче эпик әсәр. Иҗатында К.Насыйри идеяләрен дәвам итеп, халык традицияләрен өйрәнүгә зур игътибар бирә. Э.Шәрифуллина үзенең әсәрләрендә халык мәдәниятенә, аның гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, борынгы уеннарына, этнографиясенә мөрәҗәгать итә («Карга боткасы», «Каз өмәсе», «Бәби туе», «Бәби мунчасы», «Өй туе», «Кендек әбкәем», «Сабантуй» , «Ак бишектә», «Чиккән сөлге» һ.б.). 2021 елда Каюм Насыйри музеенда шагыйрә белән «Шигъри этнография» проекты оештырыла.

Әсәр: Таң чыгы. Казан, 1998; Сөюмнән мин бер чибәр идем. Казан, 2005; Каюм коесы. Казан, 2018; Тамды яшем. Казан, 2020.

Ф.Г.Камальтдинова.

ШӘФИГУ́ЛЛИНА Раушания Фаил кызы (17.06. 1969, Казан), филолог, филология фәннәре кандидаты (2000), доцент (2003), музей хезмәткәре.

Казан университеты филология факультетының журналистика бүлеген (1992) һәм шунда ук татар әдәбияты кафедрасында аспирантура тәмамлый (1999). 2000 елдан ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлегендә фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта, 2000–2009 елларда, Казан педагогика университетының әдәбият кафедрасында. 2009–2013 елларда Казан Кремле музей-тыюлыгы каршындагы Ислам мәдәнияте музее, 2013–2023

елларда *Каюм Насыйри музее* директоры.

Каюм Насыйри музее директоры буларак, мәгърифәтче-галим мирасын таныту һәм өйрәнү юнәлешендә киң колачлы, максатчан эш алып бара. Музей киңлегендәге фәнни-эзләнү эшләренә җитәкчелек итә, күргәзмә-экспозицияләрне баету һәм яңарту, бөек мәгърифәтченең китапларына багышланган презентацияләр үткәрү кебек чаралар оештыра, радио-телевидение чыгышлары, матбугаттагы язмалары аша музей эшчәнлеген таныта. К.Насыйриның 130 ел дәвамында билгесезлектә яткан «Мифтах әл-Коръән» кулъязмасын табып, 2015 елда А.*Хәйретдинов* белән автордашлыкта аның 2 томлык факсимиле вариантын әзерләп нәшер итә.

К.Насыйри «иҗтиһадымның иң олысы» дип билгеләгән «Мифтах әл-Коръән» китабы аның Ислам гыйлеме вә Коръән гыйлеме өлкәсендә зур белгеч икәнен күрсәтә. 2016–2018 елларда галимә К.Насыйриның әлеге хезмәтен таныту максатыннан Казандагы югары уку йортларында, фәнни үзәкләрдә күпсанлы презентацияләр оештыра, шулай ук Санкт-Петербург, Казан, Болгар шәһәрләрендә, Алма-Атада (Казакъстан), Әнкарада (Төркия) күпсанлы презентацияләр оештыра. Фән, мәгърифәт, әдәбият, сәнгать өлкәсендә К.Насыйри эшчәнлегенең дәвамлылыгын күрсәтү максатыннан үткәрелгән «Нурлы Казан» (2014), «Иксез-чиксез офыклар: Каюм Насыйри якташлары Фаил һәм Шәүкәт Шәфигуллиннар иҗаты» (2019), «Каюм кайтты» (2020) күргәзмәләре; «Каюм Насыйриның нәселе вә шәҗәрәсе» проекты һ.б. авторы.

Хезм.: Әдәби әсәрнең серле теле... : Фаил Шәфигуллин иҗатында шәхес фәлсәфәсе. Казан, 2003; Каюм Насыйри //



Р.Ф.Шәфигуллина

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 3 т.: XIX гасыр. Казан, 2021; Каюм Насыйриның 130 еллык кулъязмасы: Коръән өйрәнү тарихы // Татарское рукописное наследие: изучение и сохранение: материалы Всерос. науч.-практ. конф., посвящ. 130-летию С.Вахиди. Казань, 2017 (автордаш); Концепция личности в творчестве Фаиля Шафигуллина Казань, 2000; Наследие выдающегося татарского ученого-энциклопедиста Каюма Насыри в свете восточной и западной научной парадигмы // Вестник Библиотечной Ассамблеи Евразии. №1. 2018 (автордаш).

Әд.: Ганиева Р. Әтисе турында кызы // Мәдәни җомга. 2000. 10 март; Монасыйпов В. Сизгер рухы // Ватаным Татарстан. 2004, 20 август; Сафиуллина Г. Син тәмле телле ди // Сөембикә. 1994. №8; Яруллин Ф. Сөенечләр бүлешү // Мәйдан. 2003. №2.

А.Б.Насибуллина.

«ШУРА́», иҗтимагый-агарту юнәлешендәге һәм әдәби-публицистик журнал. 1908 елның 10 гыйнварыннан 1917 елның 31 декабренә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 240 саны чыга. Айга 2 тапкыр «Вакыт» газетасының кушымтасы буларак басыла. Наширләре — М.Рәмиев, аннары З.Рәмиев (Дәрдемәнд), мөхәррире — Р.*Фәхретдин*. Редакция составына Ф.Кәрими, К.Бәкер, Ш.Камал керә, журнал белән Й.Акчура, З.Бәшири, М.Бигиев, Я.Вәли, Ж.*Вәлиди* хезмәттәшлек итә. Алтын приискасы хуҗалары Рәмиевләрнең матди ярдәме белән даими югары полиграфик дәрәҗәдә чыга.

Аның төп юнәлеше Россия мөселманнары, беренче чиратта, татарлар тормышын яктырту була. Мәкаләләр дини, тарихи, мәгариф, әдәби, мәдәни, хатын-кызлар азатлыгы кебек мәсьәләләрне үз эченә ала. Сәяси бүлеге булмый, сирәк кенә рус матбугатыннан күчереп басу белән чикләнә. Мөселман бергәлеген модернизацияләүне яклый, ислам белән алгарышның, фән һәм диннең үзара ярашуын дәлилли. «Шура»да элекке мөселман мәдәнияте тарихына һәм исламның асылын аңлатуга багышланган тарихи-фәлсәфи язмалар циклы басыла; мөселман, аеруча төрки дөньяның



«Шура» журналы.

бердәмлеге ассызыклана. Педагогия, мәктәп гигиенасы мәсьәләләренә һәм уку-укыту методикасына зур игътибар бирелә. Агарту характерындагы язмаларда Европа, аеруча рус мәдәниятенең тәэсире ачык чагыла. «Атаклы кешеләр һәм мөһим вакыйгалар» бүлегендә күренекле галимнәрнең хезмәтләренә бәяләр һәм тарихи истәлекләргә тасвирламалар бирелә.

Каюм Насыйри хакындагы истәлекләрнең зур күпчелеге Ризаэтдин Фәхретдин башлангычында беренче мәртәбә элеге журналда урын ала (1912, № 21: Р.Фәхретдиннең «Габделкаюм Насыйри» язмасында — Сөләйман *Ситов* һәм Әхмәтһади *Максуди* истәлекләре; 1912, № 22: Нуретдин *Ишаев* «Каюм Насыйри хакында хатирәләр»; 1912 № 23: Һади *Тәһири* «Гаделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр», Мөхәммәткамал *Мозаффар* «Гаделкаюм әфәнде Насыйри хакында хатирәләр», Галимҗан *Акчурин* «Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле хакында кайбер мәгълүмат»; 1912, № 24: Насретдин *әл-Хуҗаши* «Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри белән мосахәбә (Хатирә дәфтәремнән)»; 1913, № 3: Мөхәммәтнәҗип *Түнтәри* «Габделкаюм Насыйри хакында хатирәтем»; 1913, № 5: Гарифулла ибне Гали Чокрый (*әл-Чокрый*) «Габделкаюм ән-Насыйри»; 1913, № 8: Мөхәммәтхәнәфи *Мозаффар* «Габделкаюм әфәнде хакында»; 1913, № 10: Габдулла бине Таҗетдин *әл-Кәчимири*. «Габделкаюм ән-Насыйри».

Әд.: Госманов М.А., Мәрданов Р.Ф. «Шура» журналының библиографик күрсәткече. Казан, 2000; Каюм Насыйри: Әдәби-тарихи һәм документаль-биографик җыентык. Казан, 2017; Мәрданов Р.Ф. «Шура» журналы (1908–1917): әдәбият мәсьәләләре. Казан, 2001; Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика начала XX в. Казань, 1966.

И.Х.Хәлиуллин.

әш-ШЫРДАНИ́ Әхмәт бине Сәгыйть (Әхмәт бине Сәгыйть бине Әхмәд бине Мөхәммәд бине Йосыф бине Габделгазиз бине Галикәй бине Габдерразак) (1787 (башка мәгълүматлар буенча, 1793), Казан губернасының Казан өязе Кишет (хәзер Татарстанның Арча районы Иске Кишет) авылы – 23 (24).05.1867, Казан), дин эшлеклесе; Каюм Насыйриның икетуган кардәше (әнисенең абыйсы Сәгыйть хәзрәтнең төпчек улы).

1831 елда Сәгыйть бине Әхмәт әш-Шырдани бишенче мәхәллә мәчете (Галиев мәчете) имамы (1810 елда мәдрәсә оештыра). Әтисе вафатыннан соң мәчетне җитәкли. 1841 елда аның тәкъдиме белән 16 яшьлек К.Насыйри Казанга килә һәм «Касыймия» мәдрәсәсендә укый башлый. Әхмәт бине Сәгыйть хакында Шиһабетдин *Мәрҗанинең* «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә түбәндәге мәгълүматлар урын алган: «1208 (1793) елның азагында, атасы Кишет авылының имамы булып торганда дөньяга килә. Мелла Габдессаттар, мелла Габделгаффар һәм мелла Габделвәлиләрнең бертуган, иң кече энеләре. Атасы мелла Сәгыйтьтән һәм бертуган абыйсы мелла Габделгаффардан, мелла Әбеннасыйр әл-Курсавидан, мелла Габдулла бине Яхъядан, Коръәнне карамыйча һәм дөрес итеп уку буенча мелла Таһир бине Сөбхан әл-Адайидан, Бохарада мелла Гаяз, мелла Гайса, мелла Габделгазиз мәхдүм казыйлардан белем ала. Туган ягына әйләнеп кайткач, ике бертуган абыйсы вафатыннан соң, әле атасы исән вакытта, 1246 (1831) елда Казандагы бишенче мәчеттә имам, хатип һәм мөдәррис булды. Озак еллар имамлык һәм хатиблык вазифаларын җиренә җиткереп үтәп, 1284 (1867) елда, сәфәр аеның икесендә, сишәмбе көнне, яше 75 тән артып киткәч вафат булды. Җеназасын абыйсының угылы мелла Габдулла укып, яңа каберлектә җирләнде. Үзеннән соң беркеме дә калмады. Сабыр һәм хуш холыклы, изге ниятле һәм аңлы кеше иде... Казанның галимнәре һәм башка кешеләре арасында кадер һәм хөрмәткә лаек булды... Безнең башлап Казанга килгән көннәребездә мәдрәсәсендә тугыз мәхдүм һәм бер шәкерте бар иде. «Җеназага еш йөри иде», — дип, халык телендә яхшылык белән искә алалар».

Әд.: Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан, 1989; Фәхретдин Р. Асар: 4 томда. 2 т. Казан, 2006.

И.Х.Хәлиуллин.

Ы

ЫРЫМНА́Р, фольклор жанры төре; тылсымлы сүз формасы. Алар жанр һәм функциональ яктан тылсымга һәм өшкерү-әфсенләүгә якын торалар. Шигъри сүзнең сихри көченә ышану, барыннан да элек, ырым, им-том, әфсен-төфсеннәрдә чагылыш таба. Ырымнар эчтәлек ягыннан мәҗүсилек гореф-гадәтләренә, йолаларга барып тоташалар, сүз һәм хәрәкәт белән башкарылалар. Борынгы төрки халыкларда алар начар һәм яхшы ырымнарга бүленә. Барлыкка килгәндә үк йола белән тыгыз бәйләнештә булганга күрә, кайбер фольклорчылар аларны йола фольклорына кертеп карыйлар.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, өйрәнүгә һәм бастырып чыгаруга аеруча зур әһәмият бирелә. Ул татар халык *әкиятләрен*, *бәетләрен*, *җырларын*, *мәкальләрен*, *сынамышларын*, *табышмакларын*, *риваятьләрен*, *ышануларын* барлау белән бергә Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендә яшәүче татар халкы арасында йөргән ырымнарны җыю һәм өйрәнүгә дә зур игътибар биргән.

Мәгърифәтче аңлатканча, Казан татарлары арасында ислам дине кысаларындагы гореф-гадәтләрдән һәм йолалардан башка мәҗүсилектән калган ырымнар һәм им-томнар да яши. Татарларның ата-бабалардан килгән ырымнары, билгеле бер эмоциональлек белән әйткәндә, табигатьтәге явыз көчләрдән, көндәлек тормыштагы бәла-казалардан саклап, авыру-чирләрдән котылып калу мөмкинлеге бирә, имеш. Мәсәлән, «Баба яки хайван үләте башлангач, авыл әйләнәсен сабан белән сызып чыгалар»; «Баланың чәчәге җиңел үтсен өчен, фәкыйрьләргә ак үрдәк, яки каз сәдака итеп бирәләр»; «Бизгәк тотып ятучы кеше арткылы аю үткәрәләр»; «Әгәр татарны котырган эт тешләсә, ул кырык йорттан икмәк борыны җыеп ала да, шуны ашый»; «Татарларның култык астына эт имчәге чыкса, аны икмәк борыны белән имлиләр».

Ырым сүзләрен әйтүче кешеләр билгеле бер эмоциональ тәэсир көченә ия булырга тиеш. Алар үз шөгыльләренең кайбер үзенчәлекләре белән кайчандыр төрки халыкларда киң таралган шаманнарны хәтерләтәләр. Аларның эш-гамәлләре һәм ниндидер магик көчкә ия саналган сүзләре, гыйбарәләре борынгы ышануларга нигезләнә. Мәсәлән, култык астына чыккан «эт имчәген» имләгәндә мондый сүзләр әйтелә: «Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз: / Тугыздан кайтсын, / Тузанга, туфракка китсен!»; «Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде: / Җидедән кайтсын, / Җилгә, күзгү китсен!»; «Бер, ике, өч, дүрт, биш: / Биштән кайтсын, / Биш юл чатлыгына китсен!»; «Бер, ике, өч: / Өчтән кайтсын, / Өч юл чатлыгына китсен!»; «Бер: / Бердән кайтсын, / Име-томы шул, имеш, / Шуны көтеб, торган

имеш / Минем кулым түгел / Гайшә Батман кулы!»

Петербург профессоры В.В.Григорьев мәгърифәтченең бу юнәлештәге эшчәнлеге турында болай дип әйтә: «Насыйровка кадәр берәү дә <...> шаманизм эзләреннән үк сакланып калган хасиятләргә мөселман дине күзлегеннән карамаган иде. Мондый төрдәге хезмәтнең зарурияте бар, һәм бер үк вакытта ул зур гыйльми табыш вәгъдә итә».

Әд: Насыйри Г.Г. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 2024; шул ук. Поверья и обряды Казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки Императорского Русского Географического Общества. По отделению Этнографии. СПб., 1880. Т. 6.

Ф.Р.Бәдретдинова, Г.И.Каюмова.

ЫШАНУЛА́Р, фольклор жанры төре. Кыска афористик формада теге яки бу хәлләрнең нәтиҗәләре турында фаразлауларны һәм юрауларны чагылдыра. Эчтәлеге ягыннан алар берничә төркемгә бүленә: 1) тамырлары архаик гореф-гадәтләргә, йолаларга илткән; 2) мәҗүсилек һәм мөселман мифологиясенә барып тоташкан; 3) татар халкының көндәлек тормышын һәм әхлакый кыйммәтләр системасын чагылдырган ышанулар. *Сынамышка* якын.

Каюм Насыйриның фәнни-гамәли эшчәнлегендә татар халык авыз иҗатын барлауга, өйрәнүгә һәм бастырып чыгаруга аеруча зур әһәмият бирелә. Ул татар халык *әкиятләрен, бәетләрен*, *җырларын*, *мәкальләрен*, *сынамышларын*, *табышмакларын*, *риваятьләрен*, *ырымнарын* барлау белән бергә Казан губернасының Зөя һәм башка өязләрендә яшәүче татар халкы арасында йөргән ышануларны җыю һәм өйрәнүгә дә зур игътибар биргән.

Мәгърифәтче фикеренчә, ышанулар татар халкының көндәлек тормышында мөһим урын алып тора, рухи-әхлакый кыйммәтләр формалашуда зур роль уйный. Татар кешесе, күк җисемнәре һәм табигать күренешләренең, йорт хайваннарының (мәче, эт, тычкан, ат), йорт һәм аның тирәсендә яши торган кош-кортларның (тавык, карга, саескан, чәүкә), теге яки бу әгъзаларының (борын, ирен, кул, колак), кием-салымының нинди дә булса хәл-халәтеннән, торышыннан чыгып, аны үзенчә юрап, киләчәген алдан белергә тырыша. Галим җыйнаган сынамышларга мисаллар: «Татарның уң колагы кычытса, җылы, сул колагы кычытса, салкын булыр»; «Кояш «колаклы» булып чыкса, салкын булыр»; «Мәче кашынса, буран булыр»; «Эт аунаса, җәй көне — яңгыр, кыш көне — буран булыр»; «Саескан кычкырса, мәче битен юса, ике кешенең маңгайлары бәрелсә яки түшәмнән ак таракан егылып төшсә, кунак килер»; «Йорт тирәсенә чәүкә ояласа, зарар китерер, шулай ук тавык әтәч булып кычкырса, зарар булыр»; «Татарлар койрыклы йолдыз күрсәләр, патшалар арасында тынычсызлык, сугыш булыр» һ.б.

Әд: Насыйри Г.Г. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 2024; Ышанулар // Татар халык иҗаты: Хрестоматия. Казан, 2005; Насыри К. Поверья и обряды Казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки Императорского Русского Географического Общества. По отделению Этнографии. СПб., 1880. Т. 6.

Г.И.Каюмова, Ф.Р.Бәдретдинова.

Э

ЭПИГРА́ФИКА (грек теленнән Epigraphē — өстендәге язу), гамәли тарих һәм филология фәннәре тармагы. Каты материаллардагы (таш, керәч, металл һ.б.) язуларның эчтәлеген һәм формаларын өйрәнү, аларны вакыт һәм мәдәни контекстлар кысаларында классификацияләү белән шөгыльләнә. Эпиграфика ядкәрләре текстлары — борынгы һәм урта гасырлар дин, сәясәт, социаль икътисад тарихы чыганакларыннан берсе.

Төрки эпиграфика истәлекләрен тикшерү Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләренең Вильгельм Томсен тарафыннан ачыклануыннан (1893), В.В.*Радлов* тарафыннан укылуыннан һәм тәрҗемә ителүеннән (1894) башлангыч ала. Татарстанда фәнни юнәлеш буларак 19 йөздә Ш.*Мәрҗани*, К.Насыйри, Х.Фәезханов, И.Н.Березин, Н.Ф.*Катанов*, Г.Н.Әхмәров хезмәтләрендә барлыкка килә.

Каюм Насыйриның күпкырлы фәнни эшчәнлегендә эпиграфика мөһим өлкә булып тора. Галим беренче булып Татарстан Республикасының хәзерге Яшел Үзән районына керүче Айдар, Бакырчы, Бәчек, Күгеш, Мулла Иле, Чуаш Республикасы Шигали авылларына нисбәтле борынгы кабер ташларын өйрәнә; шул рәвешчә, тарихчы Р.Г.*Фәхретдинов* фикеренчә, фәндә мәгълүм 16 йөз кабер ташларының саны артып, Казан ханлыгының көнбатыш тарафтагы биләмәләре ачыкланып кына калмыйча, Казан татарларының 16 йөзнең 1 нче яртысындагы тарихы, теле, гамәли сәнгате һәм рухи мәдәнияте яңа мәгълүматлар һәм элементлар белән баетыла.

Әд.: Мухаметшин Д.Г. Татарские эпиграфические памятники: Региональные особенности и этнокультурные варианты. Казань, 2008; Фахрутдинов Р.Г. Вклад Каюма Насыри в исследование истории и археологии казанских татар // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976; Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. М., 1987; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л., 1960.

И.Х.Хәлиуллин.

ЭТНОГРА́ФИЯ (грек теленнән éthnos — кабилә, халык һәм graphō — язу), халыкларны (милләтләрне) һәм башка этник бергәлекләрне, аларның килеп чыгышын, таралышын, көнкүрешен һәм мәдәни-тарихи мөнәсәбәтләрен өйрәнүче фән. Предметының нигезен аның этник йөзен билгеләүче халык мәдәнияте тәшкил итә. Этнографик мәгълүматларның зур өлеше халык тормышын турыдан-туры күзәтү (стационар һәм экспедицияләр вакытында тикшеренүләр, коллекцияләр туплау һ.б.), анкеталар тутыру һәм социологик сораштыру алымнары ярдәмендә туплана.

Казан төбәге этнографиясе турындагы беренче мәгълүматлар академия экспедицияләрендә (18 йөзнең 2 нче яртысы) катнашучылар — И.И.Геор-

ги, И.И.Лепёхин, П.С.Паллас хезмәтләрендә очрый. Россиядә фән буларак 19 йөздә формалаша. Казан университетында этнография мәсьәләләре белән И.Н.Березин, А.К.Казимбәк, О.М.Ковалевский һ.б. шөгыльләнә. Казан татарларының мәдәниятен һәм көнкүрешен башлап өйрәнүчеләрнең берсе — К.Ф.Фукс. Аның һәм шулай ук А.А.Фукс, М.С.Рыбушкин, В.С.Сбоев һ.б.ның хезмәтләреннән Казан төбәге халыклары этнографиясенең фән буларак формалашуы башлана. 19 йөзнең 2 нче яртысында — татар галимнәре Ш.*Мәрҗани*, К.Насыйри, 20 йөз башында Г.Н.Әхмәров һ.б.ның хезмәтләре барлыкка килә.

1878 елда Казан университеты каршында *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* оештырыла, 1884 елда география һәм этнография кафедрасы ачыла, системалы рәвештә этнограф белгечләр әзерләү башлана, экспедицияләр оештырыла. Җәмгыятьнең хакыйкый әгъзасы Каюм Насыйриның күпкырлы эшчәнлегендә этнографик мирасы чагыштырмача тыйнаграк урынны биләсә дә, ул этнография үсешенә зур өлеш кертә. Казан губернасының *Зөя өязе* Борнаш, Кормаш, Борындык, Айдар, Бакырчы, Бәчек, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Мулла Иле, Норлат, Югары Шырдан (*Кече Шырдан*), Цивильск өязе Шигали авылларында булып, җирле халыктан сораштырып, халык авыз иҗаты әсәрләрен (*әкиятләр*, *мәкальләр*, әйтемнәр, *табышмаклар*, *җырлар*, *бәетләр*, сынамышлар һ.б.) җыйнап туплый һәм аларны «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары», «*Император Рус география җәмгыяте язмалары*» (1880. Т.VI), «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре (табышмаклар, мәкальләр, җырлар)», «*Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре*» (1896. Т. XIII, 5 чыг.), П.А.*Поляков* белән автордашлыкта язган «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру», «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» (1900. Т. XVI, 2 чыг.) хезмәтләрендә һәм календарьларында бастыра.

Алар арасында турыдан-туры этнографиягә караган «Казан татарларының ышанулары һәм йолалары» мәкаләсе аерым урын били. Ул өч өлештән тора («Ышанулар», «Сынамышлар», «Мәҗүси йолалар һәм әфсен-өшкерүләр»); анда татарларның мәҗүси-лектән калган йолалары, хорафатлары (халык арасында таралган дөнья корылышы турында күзаллауларга бәйле булган, дини карашлардан ерак торган ышанулар), галимнең үзе тарафыннан тупланган татар халык әкиятләрендәге уйдырма затлар (судагылар — су бабасы, су иясе, су анасы, юха һәм коры җирдәгеләр — убыр, албасты, өрәк, бичура, өй иясе, абзар иясе, чәчәк анасы, чәчәк иясе, шүрәле, җен, дию пәрие) тасвирлана, әфсен-өшкерүләрдән мисаллар китерелә.

К.Насыйриның этнографиягә караган эшчәнлегенә мөнәсәбәтле Н.И.*Воробьёв*: «К.Насыйриның иң зур гыйльми әһәмияткә ия булып тора торган материаллары — аның «Бастырылмаган әсәрләре»ндәге материаллары. Ул бу әсәрләрендә материаль культура: торак, кием-салым, аш-су мәсьәләләренә кагыла. Ул шактый җентекле итеп татарларның тораклары, аларда очрый торган көнкүреш әйберләре турында сөйли, аларның әһәмиятенә, ә кайчагында килеп чыгышларына да туктала. Кием-салым турында сөйләгәндә ул аның киселешенә, тегелешенә, төсенә, материалына, кайсы яшьтәге кешеләр тарафыннан кулланылуына туктала. Аның аш-су турында язганнары урыны-урыны белән аш пешерергә өйрәтү китабына әверелеп китә, ул теге я бу ашны хәзерләү юлларын өйрәтә һәм рецептлар бирә. Шуннан соң ул татар крестьяннары-

ның туганнан алып үлгәнгә кадәр булган тормышына туктала. Ул бала туган вакыттагы гореф-гадәтләргә, баланы карауга, туйга һәм мәетне күмү мәсьәләләренә җентекле рәвештә кагыла. Тикшерүчеләрнең уена да килмәслек вак детальләрне дә төшереп калдырмый ул. Монда ул яшьләрнең көнкүрешенә, аларның кызыксынуларына, теләкләренә карата материаллар бирә. Кунакларны кабул итү, сыйлау гадәтләре детальле рәвештә тасвир ителәләр. Бу материаллар бик кыйммәтләр, көнкүреш тарихы турында фикер йөртүгә мөмкинлек бирәләр, чөнки К.Насыйри тарафыннан китерелгән көнкүреш үзенчәлекләре инде күбесе югалганнар», — дип яза.

Р.Р.Солтанова фикеренчә, турыдан-туры татар костюмы тарихына багышланган татар телендәге тәүге язмаларның авторы — К.Насыйри; 1926 елда дөнья күргән «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга» басмасының «Татар этнографиясе буенча материаллар» бүлегендә «Кием-салым» мәкаләсе урнаштырыла, анда Иделнең уңъяк яр буе Казан татарлары костюмы җентекләп тасвирлана. Галимнең этнографиягә караган фәнни эшчәнлеге Н.И.Воробьёв, Р.К.*Уразманова*, Р.Р.Солтанова һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә тикшерелә.

Әд.: Воробьёв Н.И. Каюм Насыйри — этнограф // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Насыйри Г.Г. Халык иҗаты әсәрләре, татар этнографиясе материаллары. Казан, 2024; Бусыгин Е.П., Зорин Н.В. Этнография в Казанском университете. Казань, 2002; Воробьёв Н.И. К.Ф.Фукс — первый исследователь быта казанских татар // Вестник Научного общества татароведения. Казань, 1927. № 6; Уразманова Р.К. Каюм Насыри как этнограф // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. Казань, 1976.

И.Х.Хәлиуллин.

Ю

ЮБИЛЕ́Й ТӘҢКӘСЕ́, истәлекле көмеш тәңкә. «Россиянең атаклы шәхесләре» сериясеннән Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышлап «пруф» сыйфатында сугылган.

Россия банкы тарафыннан 2025 елның 15 гыйнварында 3 мең данәдә чыгарыла. Номиналы — 2 сум. Кыйммәтле металлның чиста массасы — 15,55 г, коелма пробасы — 925. 33,0 мм диаметрлы түгәрәк рәвешендә.



Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышлап чыгарылган көмеш тәңкә. 2025.

Йөз ягы һәм арткы ягы әйләнә буенча кабарынкы кант белән каймаланган. Акчаның йөз ягында үзәктә — РФ Дәүләт гербы сурәте, өстә — «Россия Федерациясе», аста «Россия банкы» язулары урнаштырылган, Россия Дәүләт гербының аскы өлешенең сул ягында — Д.И.Менделеевның Элементлар периодик системасы буенча металл тамга-билгеләмәсе һәм коелма пробасы, уң ягында кыйммәтле металлның чиста массасы һәм Санкт-Петербург акча сугу сараеның товар билгесе күрсәтелгән. Акчаның арткы ягында лазер белән тонык ландыру техникасында башкарылган китап киштәләре фонында рельефлы К.Насыйри һәм китаплар куелган өстәл сурәте, өстә уң якта әйләнә буенча «Каюм Насыйри» («Каюм Насыри»), аста уң якта, ике юлга бүленеп, «1825» һәм «1902» язулары урнаштырылган. Акчалата түләүнең законлы берәмлеге.

И.Х.Хәлиуллин.

ЮСУ́ПОВА Әлфия Шәүкәт кызы (24.03.1966, Татарстанның Чүпрәле районы Иске Шәйморза авылы), тел галиме, филология фәннәре докторы (2009), профессор (2010), РФнең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре (2016), ТРның атказанган югары мәктәп хезмәткәре (2020).

Казан университетын тәмамлаганнан соң (1988), шунда ук татар филологиясе һәм тарихы факультетында эшли: 2008 елдан гамәли лингвистика һәм тәрҗемә теориясе һәм сөйләм коммуникациясе кафедрасы мөдире. 2011 елдан Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында (2013 елдан Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты) тәрҗемә теориясе һәм мәдәниятара багланышлар, 2013 елдан татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар кафедралары мөдире, 2015 елдан Габдулла Тукай исемендәге Татаристика һәм тюркология югары мәктәбе директоры, 2019 елдан гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы профессоры; бер үк вакытта, 2016 елдан,

Каюм Насыйри институты директоры.



Ә.Ш.Юсупова

Хезмәтләре татар теленең 19 йөзгә караган икетелле лексикографиясенә, татар теле лексикологиясенә, диаспора теленә һәм башкаларга карый. Урта мәктәпләр өчен татар теленнән дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре авторы. К.Насыйриның русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр булдыруга керткән өлешенә багышланган мәкаләләрендә галимнең «Әнмүзәж», «Татарча-русча лөгать китабы» һәм башка әсәрләренең әһәмияте югары бәяләнә, аларның авторы кулланган принциплар, алымнар һәм ысуллар яктыртыла, аның тел белеме өлкәсендә генә түгел, фәннең төрле тармаклары буенча эшчәнлеге барышында да заманча татар әдәби теле нигезләренә башлангыч биргән галимнәрнең берсе булуы ассызыклана.

Казакъстан халыклары ассамблеясенең «Берлек» алтын медале, Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Хезм.: Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. Казань, 2008; Лексикографическое и методическое наследие татарского языка (XIX век). Казань, 2010; Вклад К.Насыри в создание татарско-русских и русско-татарских словарей XIX века // Востоковедение в России и странах СНГ на рубеже веков: материалы международного симпозиума, посвященного 200-летию создания кафедры восточной словесности в Казанском университете. Казань, 2015; Об одном словаре Каюма Насыри // Татарская поэзия и культура второй половины XX – начала XXI века: диалог с западными и восточными художественными традициями (к 80-летию татарского поэта Рената Хариса). Казань, 2021.

Әд.: Казанская лингвистическая школа. Казань, 2008.

И.Х.Хәлиуллин.

Я

ЯГЪФӘ́РОВА Рәдинә Хәким кызы (13.01.1944, Пермь өлкәсенең Барда районы Байавыл авылы – 06.04.2023, Пермь краеның Барда районы Барда авылы), педагог, педагогия фәннәре кандидаты (1997), РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы (1980), ТРның атказанган укытучысы (1993). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2002).



Р.Х.Ягъфәрова

Усы педагогия училищесын (1962), Казан университетының тарих-филология факультетын (1969), педагогика һәм психология кафедрасы аспирантурасын (1974) тәмамлый. 1962–1964 елларда — Сараш мәктәбендә, 1969–1971 елларда Әлмәт районы Габдрахман мәктәбендә укыта. 1974 елдан — Татарстан укытучылар белемен күтәрү институты методисты, башлангыч белем бирү кабинеты мөдире, 1986 елдан — Казан педагогика училищесы укытучысы, 2012 елдан — ТР Мәгарифне үстерү институты доценты.

Эшчәнлеге башлангыч сыйныфларда татар һәм рус телләрен укыту методикасына, дәреслекләр язуга, методик кулланмалар төзүгә карый. «Әлифба»ны төзүче буларак та билгеле.

Хезм.: Уку китабы: Рус мәктәбенең 3 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек. Казан, 1994; Әлифба: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе. 1 нче сыйныф өчен дәреслек. Казан, 2012; Уку дәресләре. 1–4 нче сыйныфлар: методик кулланма. Казан, 2015.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиографический словарь. Казань, 2004. Т. 3; Кто есть кто: авторы издательства «Магариф». Казань, 2002.

Ф.С.Гыйниятуллина.

ЯЗМА́ МИРА́С ҮЗӘГЕ́, ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының структур берәмлеге. Үзәк 2007 елда мөстәкыйль кулъязмалар һәм фәнни архив бүлеге буларак оештырыла, 2011 елдан — Язма һәм музыкаль мирас үзәге, 2022 елдан — хәзерге исемдә. Үзәкнең төп фәнни эшчәнлеге кулъязмалар һәм сирәк китапларны җыйнау-туплау, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең, галимнәрнең хосусый архивларын алдыру, аларны гыйльми нигездә эшкәртеп, тасвирламаларын төзүдән, системага салып фәнни кулланылышка кертүдән гыйбарәт.

Максатчан рәвештә материаллар туплау ТАССР Халык мәгарифе комиссариаты каршындагы *Гыйльми үзәк* тарафыннан ук башлана. Әмма әлеге фәнни оешманың структурасына кай-

бер үзгәрешләр кертелү һәм аның җитәкчесе Галимҗан Ибраһимовның авыруы сәбәпле, бу юнәлештә эш туктап кала. Җыйналган материаллар башка оешмалар карамагына күчә һәм алга таба бөтенләй юкка чыга.

1939 елның 7 октябрендә Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты оештырылганнан соң, язма истәлекләрне, язучыларның хосусый архивларын ачыклау, туплауга зур игътибар бирелә. Мәсәлән, 1940 елның гыйнварыннан татар язучылары Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Каюм Насыйри һ.б.ның хатлары, документлары, кулъязмалары, фотолары җыйнала башлый. Әмма, кулъязмалар бүлеге кебек аерым структур берәмлек булмау сәбәпле, алар институтның фәнни китапханәсенә урнаштырыла. Әлеге китапханә 1950 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалында ачылган Фәнни китапханәнең нигезен тәшкил итә. Институт документлары коллекциясенең бер өлешен тәшкил иткән кулъязмалар 1960 елның декабренә 784 берәмлек санала.

1960 елның 1 июлендә СССР Фәннәр академиясенең Фәнни китапханәсендә архив фонды оештыру турында карар чыга. Аны гамәлгә ашыру максатында фондларны һәм материалларны тасвирлау өчен методик документ әзерләнә. Аның нигезендә 1961 елның 15 июлендә китапханәдә тупланган кулъязма материалларны тасвирлау эше башлана һәм ул Х.Г.Сайманова га йөкләнә (1914–1988). Беренче булып, Г.Тукай фонды төзелә һәм эшкәртелә.

1963 елның 3 маенда архив Казан физика-техника институты карамагына тапшырыла. 1972 елның мартында Тел, әдәбият һәм тарих институтында архив оештырылгач, Казан физика-техника институты архивыннан 41 эшкәртелгән һәм тасвирланган фонд, 75 тасвирлама, 5843 саклау берәмлеге, 40 берәмлек фонд эшләре күчерелә. Әмма күп материаллар элекке урынында кала.

Архив яңа документлар белән тулылана башлый, лаборант штаты булдырыла. 1976–1986 елларда аның җитәкчесе булып тарихчы Г.М.Дәүләтшин эшли, тагын бер хезмәткәр штаты арттырыла. Башта архив институтның зур булмаган бер бүлмәсендә урнаша. 1988 елда ул кулъязмалар һәм текстология бүлеге белән бергә Ленин (хәзер Кремль) урамындагы зур бинага күчерелә. 2008 елның апрелендә кулъязмалар, фәнни һәм архив фондына «Казан Кремле», Казан дәүләт тарих һәм сәнгать музей-тыюлыгындагы «Манеж» бинасының бер өлеше



Язма мирас үзәге.

бирелә. 2011 елда ул Язма һәм музыкаль мирас үзәге статусы ала.

Хәзерге вакытта Үзәктә 200 дән артык фонд бар, алар түбәндәгеләрне үз эченә ала: 1) татар, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендәге кулъязма китаплар; 2) язучыларның, мәдәният һәм сәнгать әһелләренең хосусый архивлары; 3) татар әдәбияты һәм тел гыйлеме, тарихы, сәнгате, этнографиясе, классик татар һәм рус драматургиясе, фольклоры, мәгарифе, экспедиция материаллары, фотокопияләр һәм микрофильмнар, шәҗәрәләр, Бөек Ватан

сугышы фронтларыннан хатлар коллекцияләре; 4) ТР Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы; 5) гарәп графикасындагы татар көндәлек матбугаты һәм басма китаплар коллекциясе.

Кулъязма китаплар фондын Әхмәд Ясәви (11 йөз), Сөләйман Бакыргани (12 йөз), Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» (50 дән артык нөсхә) (13 йөз), Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (14 йөз), Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (14 йөз), Өмми Камал (15 йөз), Мөхәммәдъярның «Нуры содур» һәм «Төхфәи мәрдан» (16 йөз), Сәйядиның «Дастаны Бабахан» (17 йөз), Мәүла Колый (17 йөз), Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» (17 йөз), Габдерәхим Утыз-Имәни (18 йөз), Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (18 йөз уртасы — 19 йөзнең 1 нче чиреге), Мифтахетдин Акмулла (19 йөз) әсәрләре, төрле дастаннар һ.б. тәшкил итә.

Тупланмада Хәким Сәнаи (1150 ел тирәсендә вафат), Фәрideддин Гаттар (1120–1229), Җәлаледдин Руми (1207–1273), Сәгъди Ширази (1292 елда вафат), Габдерахман Җами (1414–1492), Шәрәфеддин Бусыри (1213–1296), Гали ибне Әбуталиб (якынча 661 елда вафат) һәм башка күренекле фарсы һәм гарәп шагыйрьләренең иҗат үрнәкләре саклана.

Кулъязма Коръән нөсхәләре (160 тан артык) Үзәкнең кыйммәтле фонды булып тора. Шулай ук күп санда тәфсирләр, шәҗәрәләр, авыл тарихлары, мөселман хокукы документлары, метрика дәфтәрләре, календарьлар, васыятьнамәләр һәм башка документлар бар.

Язучылар, мәдәният һәм сәнгать әһелләреннән күренекле дин белгече һәм реформатор, тарихчы Шиһабетдин *Мәрҗани* (1818–1889), күренекле әдипләр Шакир Мөхәммәдов (1865–1923), Фатих Кәрими (1870–1937), Сәгыйть Рәмиев (1880–1926), Гафур Коләхмәтов (1881–1918), Шәриф Камал (1884–1942), Фатих *Әмирхан* (1886–1926), Кәрим Тинчурин (1887–1938), Зариф Бәшири (1888–1960), Сәгыйть Сүнчәләй (1889–1937), Гали Рәхим (1892–1943), Фәтхи Бурнаш (1898–1942), Һади Такташ (1901–1931), Кави Нәҗми (1901–1957), Гомәр Бәширов (1901–1999), Гадел Кутуй (1903–1945), Риза Ишморат (1903–1995), Муса Җәлил (1906–1944), шул исәптән балалар шагыйре, драматург Дәрҗия Аппакова (1898–1948), әдәбият галимнәре Мөхәммәт *Гали* (1893–1952), Гали *Халит* (1915–1992), библиограф, татар көндәлек матбугаты белгече, тәрҗемәче Исмәгыйль Рәмиев (1895–1969), тюрколог Николай *Катанов* (1862–1922), археолог, тарихчы Николай Калинин (1888–1959), археограф Сәид (Сәидгаттар) Вахиди (1887–1938), миссионер Ефим Малов (1835–1918), композитор Солтан Габәши (1891–1942), журналист, мөгаллим Вафа *Бәхтияров* (1886–1960), балалар шагыйре, тел галиме Василий Богородицкий (1857–1941), Шиһабетдин Рамазанов (1887–1948), танылган дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм галим Галимҗан *Ибраһимов* (1887–1938) һ.б.ның фондлары саклана.

Татар сәнгатенә караган материаллар Үзәк фондларының шактый өлешен тәшкил итә. Аерым алганда, алар — 20 йөз башыннан хәзерге вакытка кадәр 1000 нөсхәдән артык театр афишалары һәм музыка-этнография экспедицияләрендә язып алынган 6000 җыр һәм көй язмалары.

1969 елдан башлап Татарстан, Башкортстан, Чуаш, Мари, Мордва республикаларында, Әстерхан, Ульяновск, Чиләбе, Оренбург, Курган, Пенза, Киров, Свердловск, Омск өлкәләрендә, Пермь краенда һәм РФнең башка төр-

бәкләрендә археографик экспедицияләр оештырыла.

Тупланмадагы материаллар фәнни әйләнешкә кертелә: алар күптомлы фундаменталь хезмәтләрдә, монографияләрдә, тематик фәнни җыентыкларда, диссертацияләрдә ачык чагылыш таба. Аерым әсәрләр, язма истәлекләр текстологик яктан әзерләп бастырыла, тасвирламалар нәшер ителә.

Үзәк фондларындагы материаллар белән ерак һәм якын чит ил, РФнең төрле төбәкләреннән галимнәр шөгыльләнә.

2010 елда Үзәкнең фондлары заман таләпләренә җавап бирә торган яңа стеллажлар (аларның 30 ы — күчерелмәле, 6 сы — стационар; барлыгы 1200 м) белән тәэмин ителә. Бинаның икенче катында реконструкция ясала. Нәтиҗәдә, зур уку залы, хезмәткәрләр һәм техник эшләр өчен аерым бүлмәләр барлыкка килә. Яңа компьютерлар, сканер, принтер, ксерокүчерү аппаратлары һәм башка техник җайланмалар алына.

Үзәк һәм аның фәнни хезмәткәрләре «Шәрекъ кулъязмалары: өйрәнелүнең хәзерге торышы һәм алдагы бурычлар» (2011), «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен өйрәнү проблемалары» (2013) түгәрәк өстәлләрен, Казан Кремлендәге Колшәриф мәчетенең Ислам мәдәнияте музеенда «Кол Гали. «Кыйссаи Йосыф» — мәхәббәткә мәдхия» күргәзмәсен (2013), Казан Кремленең «Манеж» бинасында «Татар халкының рухи тормышында кулъязма Коръән» (2013) күргәзмәсен, шул күргәзмә кысаларында Иран Ислам Җөмһүриятенең Казандагы Баш консуллыгының мәдәният буенча Атташаты белән берлектә «Коръән — мөселманнарның рухи мирасы хәзинәсе» (2013) түгәрәк өстәлен, Төркиянең Казандагы баш консуллыгы, Төркиянең Юныс Әмрәне өйрәнү буенча Казандагы Үзәге катнашында «Төрек әдәби мирасының татар рухи мәдәниятендә роле» (2014) түгәрәк өстәлен оештыра һәм уздыра.

Үзәктә күренекле татар галиме Каюм Насыйриның (1825–1902) аерым фонды (11) бар. Ул биш тасвирлама, 111 саклау берәмлеген тәшкил итә. 1967 елда Х.Г.Сайманова тарафыннан төзелгән. Документлар арасында мәгърифәтченең автографлары (хезмәтләренең рус телендәге исемлеге, 1871–1872 елларда төзегән календарьлары, русча-татарча сүзлекнең, «Краткая татарская грамматика» китабының, геометрия, география дәреслекләренең кулъязмалары, хисап дәреслеге фрагменты; 1840–1894 елларда әтисенә, әнисенә, абыйсы Габделхәйгә, башка туганнарына, кардәшләренә язган һәм үзенә килгән хатлар; үзенә кагылышлы документлар: үзенең һәм әтисенең паспортлары, васыяте, шәҗәрәсе, тормышы белән бәйле биналарның фотосурәтләре, дәгъватнамәләр (чакыру кәгазьләре), хезмәтләрен бастыру турында язышу кәгазьләре; аның турында замандашларының истәлекләре, газета кисемтәләре, хезмәтләренең титул битләре сурәтләре һәм башка материаллар; 1898–1925 елларда төрле кешеләр тарафыннан язылган язмалар (Пётр *Масловскийның* гомуми тарих буенча планнары, үзенең укытучысы Шәмсетдин Шәмсуаров хатларының фотокүчермәләре, миссионер мәктәбе укытучысының татар теле турында язмасы) бар. Кара: *Кушымта 3*.

Мөдирләре: М.И.Әхмәтҗанов (2007–2009), Р.Ф.*Исламов* (2009–2015), И.Г.Гомәров (2015 елдан).

Әд.: Әхмәтҗанов М.И. Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. Казан, 2005; Исламов Р.Ф. Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изу-

чения: материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.). Казань, 2011.

Р.Ф.Исламов.

ЯМАЛТДИ́НОВА Сөгъдә Таһир кызы (31.08.1960, Татарстанның Лениногорск районы Түбән Чыршылы авылы), филолог, укытучы. РФнең Халык мәгарифе отличнигы (1994). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2010).

Казан университеты филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый (1985). 1977–1982 елларда – Түбән Чыршылы урта мәктәбендә, 1983–2016 елларда Керкәле урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта.


С.Ямалтдинова иҗади сәләтен мәгърифәтче Ризаэтдин *Фәхретдин* мирасына нигезләнгән милли тәрбия бирүгә багышлый. ТР дәүләт радиосының күптөрле татарча тапшыруларын өйрәнеп, алардан балаларга милли, рухи-әхлакый тәрбия бирүдә уңышлы файдалана; шуларга нигезләнеп, «Ризаэддин Фәхреддин мирасы» һәм «Балкыш тапшыруы» авторлык программасы төзи. Татарстан дәүләт радиосының «Балкыш» тапшырулар циклы үрнәгендә 2001 елда үзенең укучылары белән мәктәпнең «Балкыш» студиясен ачып җибәрә һәм аның җитәкчесе була (15 ел эшчәнлек алып бара). Балаларда иман, әдәп-әхлак тәрбияләүгә зур көч куя. «Ризаэддин Фәхреддин хезмәтләрен дәрестән тыш эшләрдә файдалану тәҗрибәсеннән» хезмәте һәм мәкаләләр авторы.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнә.

Ф.С.Гыйниятуллина.



С.Т.Ямалтдинова



Ф.Ж.Ямбушев

Я́МБУШЕВ Фәрит Җамалетдин улы (22.04.1940, Мордва АССРның Ләмбрә районы Ләмбрә авылы), химик-органик, химия фәннәре докторы (1992), профессор (1993), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2008), ТРның атказанган фән эшлеклесе (2002). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2019).

Казан педагогия институтын тәмамлый (1967), шунда ук эшли. 2011 елдан Казан федераль университетының А.М.Бутлеров исемендәге Химия институтында.

Хезмәтләре синтез ысулларын эшләү, мышьяк чыгарылмаларының электрон үзлекләрен һәм реакцион мөмкинлекләрен өйрәнүгә карый. Галим мышьяк чыгарылмаларыннан йөрәк эшчәнлеген яхшырта торган, гөмбә, бактерия, микробларга каршы көрәшүче кушылмалар ала һәм шулар нигезендә полимер стабилизаторлары, нәтиҗәле фунгицидлар барлыкка китерә. Югары уку йортлары өчен татар телендә органик химия дәреслекләре авторы. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

«Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», СССР ВДНХсының көмеш медальләре, РФ Мәгариф министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнә.


Хезм.: Органик химия. Лаб. практикум: югары уку йортлары өчен уку әсбабы. Казан. 2006; Кызыклы химия: уку яр-

дәмлеге. Казан. 2017; Стереохимия мышьякорганических соединений // Успехи химии. Мышьякорганические 1979. Т. 48, № 6 (автордаш); Синтез, свойства и димеризация диарилбром- и арилдибромарсазосоединений // Журнал общей химии. 1991. Т. 61, вып. 10 (автордаш).

Әд.: История Мордовии в лицах: Биографический сборник. Саранск, 1997. Кн. 2; Учёные Татарского гуманитарно-педагогического университета. Казань, 2008.

Ф.Г.Камальтдинова.

«ЯҢА́ МИЛЛИ́ ЮЛ», иҗтимагый-сәяси, фәнни-әдәби журнал. 1928 елның 23 декабреннән 1939 елның октябренә кадәр Берлинда, Варшавада


YAÑA MILLI YUL

Chefredakteur und Herausgeber: A. Ishaki

Jahrg. 8 | Februar 1936 | Hr. (96) 2

REDAKTION „YAÑA MILLI YUL"

Berlin-Charlottenburg 1

Postfach Nr. 8

«Яңа милли юл» журналы.

татар телендә айга 2 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 136 саны чыга. 1930 елга кадәр «Милли юл» исеме белән басыла. Гарәп графикасы кулланыла, кайбер язмалар немец, кырым-татар, төрек телләрендә дөнья күрә. Нашире һәм мөхәррире — Гаяз *Исхакый* (баштагы 19 санында «К.Русак» тәхәллүсе белән яза). Газетаны чыгарырга Г.Х.Терегулов ярдәм итә. Һәр санда халыкара вакыйгаларга күзәтү ясала.

Журнал руслаштыруны, СССР халыкларын дин ирегеннән һәм милли азатлыктан мәхрүм итүне кискен тәнкыйтьли. Төрки халыкларның милли азатлык хәрәкәте эшлеклеләренә, татар халкының атаклы вәкилләренә (Йосыф Акчура, Габдерәшит Ибраһимов, Шиһабетдин *Мәрҗани*, Каюм Насыйри, Фоат Туктаров һ.б.) зур игътибар юнәлтелә. Г.Исхакый публицистикасының төп юнәлеше азатлык, татар халкының тарихи истәлекләрен яңарту, тоталитар режим шартларында милләтнең үзсаклануы идеяләреннән гыйбарәт була. Журналның 1937 елгы санында аның «Гаяз» тәхәллүсе белән «Габделкаюм ән-Насыйри» язмасы басыла; мәкаләдә галимнең мәгърифәтчелек, төрле фәннәр, татар тел белеме тармакларындагы эшчәнлеге югары бәяләнә, татар мәгарифе үсешенә зур өлеш кертүе ассызыклана. Басмада татар теле һәм әдәбияты үсеше мәсьәләләренә, татарларның милли-мәдәни тәңгәллегенә зур урын бирелә. Заманча татар мәктәбенең төп бурычы сыйфатында әдәби телне яхшы белгән киң белемле буын әзерләү максаты куела.

Әд.: Гаяз (Исхакый Г.) Габделкаюм ән-Насыйри // Яңа милли юл. 1937. № 10; Миңнегулов Х. Азатлык көрәшенең мөнбәре // Казан утлары. 1993. № 3.

И.Х.Хәлиуллин.

ЯРМИ́ (Ярмөхәммәтов) Хәмит Хөснетдин улы (05.05.1904, Тобол губернасының Төмән өязе Казар (хәзер Төмән өлкәсенең Төмән шәһәр округы Кырынкүл) авылы – 30.10.1981, Казан), фольклорчы, филология фәннәре докторы (1972), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1964), ТАССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1989).

Туган авылы мәдрәсәсендә белем ала. Казандагы Татар педагогия институтын тәмамлый (1934). 1923 елдан — Төмән шәһәрендә: «Юксыллар чаткысы» газетасында җаваплы сәркатип, шәһәр китапханәсендә мөдир, мәктәптә укытучы. 1925–1929 елларда — Төмән өлкәсенең Яркәү авылында: ВКП(б) район комитетында инструктор, халык мәгарифе бүлегендә инструктор. 1934 елдан — Казандагы «Кызыл Татарстан» газетасында мәдәният бүлеге мөдире, ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркатип, Татарстан китап нәшриятында мөхәррир. 1939 елдан — ТАССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы Тел, әдәбият һәм тарих институтында (1942–1944 елларда — директор), 1945–1971 елларда — СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында, 1961 елдан — халык иҗаты секторы мөдире. 1940–1950 елларда — Татарстан, Удмурт, Мордва АССРларында, Киров, Пенза, Рязань һәм башка өлкәләрдә татар халык фольклорын җыю буенча оештырылган экспедицияләргә җитәкчелек итә. «Халык иҗаты» (1938), «Татар халык иҗаты» (1951), «Татар халык әкиятләре» (1–2 т., 1946–1956), «Бәетләр» (1960), татар фольклорының күптомлы «Татар халык иҗаты» җыентыкларын басмага әзерләүдә катнаша.

Хезмәтләре татар фольклоры жанрларына, татар халык авыз иҗаты тарихына карый. Урта мәктәпләр өчен татар фольклоры буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы. Каюм Насыйри турындагы мәкаләләрендә галимнең татар халык авыз иҗатын җыйнау һәм дөньяга чыгарудагы эшчәнлеге, бу юнәлештәге алымнары һәм принциплары яктыртыла, милли фольклорны әсәрләрендә уңышлы кулланыу, системага салу омтылышы югары бәяләнә; К.Насыйриның авылдашларыннан (Гыйбадулла *Төхфәтуллин*, Талип *Гайсин*, Гыйльман *Ногманов*, Мәсхәпҗамал *Ибәтуллина*, Гатаулла *Дусаев*) мәгърифәтче турындагы истәлекләрне язып ала.



Х.Х.Ярми



А.Г.Яхин

«Почёт билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Югары Шырдан авылында // Кызыл Татарстан. 1945. 4 февраль; Татар фольклорын җыйнау һәм аны бастырып чыгару өлкәсендә Каюм Насыйриның эшчәнлеге // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948; Татар халкының поэтик иҗаты. Казан, 1967.

Әд.: Хәмит Ярми: Галим һәм шәхес. Казан, 2004; Народно-поэтическое творчество // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967.

И.Х.Хәлиуллин.

Я́ХИН Альберт Гатуф улы (08.11.1931, Татарстанның Арча районы Арча эшчеләр бистәсе – 02.10.2010, Казан), әдәбият галиме, фольклорчы, журналист, филология фәннәре кандидаты (1964), РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1973), СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1977). ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Каюм Насыйри исемендәге бүләге лауреаты (2001).

Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган-

нан соң, 1954–1956 елларда Азнакай районы Тымытык урта мәктәбендә уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1959 елдан «Чаян» журналында баш мөхәррир вазифаларын башкара. 1975–1981 елларда — Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире.

Хезмәтләре сәясәт эшлеклесе, язучы Шамил Усманов иҗатына, татар фольклоры әсәрләрен һәм жанрларын системалы өйрәнүгә карый. Ш.Усмановның фаҗигале тормыш юлына нигезләнеп, Аяз Гыйләҗев белән берлектә «Шамил Усманов» тарихи драмасын яза. Аның шулай ук юмористик жанрда дистәләрчә сатирик хикәясе һәм фельетоннары дөнья күрә. Аларның бер өлеше «Әйттем исә кайттым» (1975) дигән исем белән аерым китап булып басылып чыга, рус теленә дә тәрҗемә ителә. А.Яхин дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр, урта мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан эшләнмәләр авторы буларак та билгеле.

Хезм.: Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәжрибәсе. Казан, 1979 (автордаш); Әдәбият дәресләре: укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укучылар өчен методик кулланма. Казан, 2003; Система татарского фольклора. Казань, 1984.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. Казан, 2009. 2 т.; Заһидуллина Д. Заманнан алда // Ватаным Татарстан. 2001. 9 ноябрь; Мозаффарова М. Яхин программасы — нинди ул? // Фән һәм мәктәп. 1996. № 1.

Ф.С.Гыйниятуллина.

КУШЫМТАЛАР

Кушымта 1

КАЮМ НАСЫЙРИ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ ЛАУРЕАТЛАРЫ

	Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме	Бүләкләнү елы
1	*Акашина* Нилә Мөхәммәт кызы	2015
2	*Арсланова* Рәхимә Минвәли кызы	2014
3	*Әхмәдуллин* Азат Гыйльмулла улы	1999
4	*Борһанова* Рәшидә Габдрахман кызы	2007
5	*Вагыйзов* Сәләй Гатат улы	1988
6	*Вәлитова* Рәмзия Гыйлаҗ кызы	1988
7	*Вәлиуллин* Мәҗит Әгъли улы	2008
8	*Габделганиева* Мәдинә Хәниф кызы	1989
9	Габдерәүпов Равил Габдерәүп улы	1992
10	*Габдуллин* Габделхан Габдулла улы	2007
11	*Гайфуллин* Васил Габдулла улы	2004
12	*Галиева* Ләлә Исмәгыйль кызы	1995
13	Галиева Наилә Гали кызы	2013
14	*Гариф* Нурулла Гыйматдин улы	2015
15	Гыймадиева Гадилә Нургали кызы	
16	*Җамалетдинова* Зәлфирә Исхак кызы	2009
17	*Җәләлиев* Шамил Шәйхи улы	2005
18	*Закирова* Кафия Вәли кызы	2017
19	Зарипов Радик Абдулла улы	2010
20	Зарипов Роберт Сәйдел улы	
21	Ибраһимова Зәкия Ибраһим кызы	
22	*Исламов* Рәмил Фәнәви улы	2023
23	*Исхакова* Рима Мөхәррәм кызы	2014
24	*Казыйханов* Вил Суфиян улы	2002
25	*Камалов* Абрик Закир улы	2013
26	*Максимов* Николай Валентинович	2003
27	*Мансуров* Роберт Мияссар улы	2024
28	*Маһиярова* Зилә Миннегаян кызы	2012
29	*Мәхмүтова* Фәүзия Таһир кызы	2010

30	*Минһаҗева* Ләйлә Ихсан кызы	2010
31	*Миңнуллин* Роберт Мөгаллим улы	2010
32	*Мирхазова* Нурзия Рәшит кызы	2020
33	*Мияссарова* Илсөяр Хәбибулла кызы	2010
34	*Мөхәммәтгәрәева* Гөлфия Вагыйз кызы	2003
35	*Мөхәммәтҗанов* Ильяс Мулланур улы	2013
36	*Низамов* Айдар Малик улы	2008
37	*Низамов* Равил Авзал улы	2008
38	*Нуриева* Алмазия Хаҗи кызы	
39	*Садриев* Әхәт Шәйхи улы	1997
40	*Сафиуллина* Флера Садри кызы	2001
41	*Туктамышев* Наил Кадыйр улы	2013
42	*Фәизова* Фирая Сафа кызы	2016
43	*Фәтхуллова* Кадрия Сөнгат кызы	2012
44	*Ханбиков* Якуб Исхак улы	2000
45	*Харисов* Фираз Фәхразый улы	1997
46	*Харисова* Чулпан Мөхәррәм кызы	1997
47	*Хәбибуллина* Закирә Нури кызы	2008
48	*Хәбибуллина* Люция Бәдретдин кызы	2016
49	*Хәйдәрова* Роза Зәки кызы	2022
50	*Хәйруллин* Әнвәр Нәҗип улы	2004
51	*Хәмидуллина* Мәрзия Зәки кызы	2012
52	Хөсәенова Кадрия Хафиз кызы	2008
53	*Хуҗиәхмәтов* Әнвәр Нуриәхмәт улы	2001
54	*Шакиржанов* Рәшит Әгълә улы	2013
55	Шакиржанова Әлфия Бари кызы	
56	*Шәмсетдинова* Рәсимә Равил кызы	2008
57	*Шәрәфетдинов* Вил Ширияздан улы	2004
58	*Шәрифуллина* Эльмира Мөхәмәтулла кызы	2021
59	*Ягъфәрова* Рәдинә Хәким кызы	2002
60	*Ямалетдинова* Сөгъдә Tahир кызы	2010
61	*Ямбушев* Фәрит Җамалетдин улы	2019
62	*Яхин* Альберт Гатуф улы	2001

	КОЛЛЕКТИВЛАР	
1	*Алтмыш җиденче балалар бакчасы* (Казан шәһәре Совет районы)	2022
2	Алтмыш җиденче һөнәр училищесы (Чаллы шәһәре)	
3	Арча педагогика көллияте (Арча шәһәре)	2007
4	Ачасыр урта мәктәбе (Яшел Үзән районы)	1989
5	«*Әкият*» балалар бакчасы (Мамадыш шәһәре)	2019
6	«Әллүки» балалар бакчасы (Саба районы)	2005
7	Бәләбәй татар гимназиясе (Башкортстан Республикасы Бәләбәй шәһәре)	2003
8	«Бәләкәч» балалар бакчасы (Чаллы шәһәре)	2016
9	Беренче татар гимназиясе (Казан шәһәре Вахитов районы)	2002
10	Бима урта мәктәбе (Әгерҗе районы)	2013
11	Бишенче гимназия (Казан шәһәре Авиатөзелеш районы)	
12	Бишенче гимназия (Яшел Үзән шәһәре)	2005
13	Дүрт йөз унбишенче балалар бакчасы (Казан шәһәре Совет районы)	2003
14	Дүртенче гимназия (Казан шәһәре Киров районы)	2010
15	*Егерменче гимназия* (Казан шәһәре Совет районы)	2020
16	Егерме җиденче гимназия (Казан шәһәре Вахитов районы)	2012
17	Егерме тугызынчы педагогика лицее (Чаллы шәһәре)	
18	Зур Сәрдек урта мәктәбе (Кукмара районы)	
19	Иж-Буби урта мәктәбе (Әгерҗе районы)	
20	Ике йөз алтмыш беренче балалар бакчасы (Казан шәһәре Совет районы)	2024
21	Икенче татар гимназиясе (Казан шәһәре)	
22	Илле сигезенче рус-татар мәктәбенең «Бердәмлек» берләшмәсе (Казан шәһәренең Совет районы)	
23	Имәнкискә урта мәктәбе (Лаеш районы)	
24	«Йолдыз» балалар бакчасы (Биектау районы)	2021
25	Йөз алтмыш җиденче урта мәктәп (Казан шәһәре Совет районы)	2009
26	*Йөз илле бишенче гимназия* (Казан шәһәре Яңа Савин районы)	2016
27	Йөз кырык тугызынчы лицей (Казан шәһәре Совет районы)	2008
28	Йөз сиксән өченче балалар бакчасы (Казан шәһәре Совет районы)	2023

29	«Камыр батыр» балалар бакчасы (Чаллы шәһәре)	2011
30	*Карадуган балалар бакчасы* (Балтач районы)	
31	Карадуган урта мәктәбе (Балтач районы)	2008
32	*Кече Елга гомуми белем мәктәбе* (Лаеш районы)	2012
33	«Кояшкай» балалар бакчасы (Зәй районы)	2009
34	«Кояшкай» балалар бакчасы (Мөслим районы)	2010
35	«*Көнбагышкай*» балалар бакчасы (Чаллы шәһәре)	2015
36	Олы Кукмара урта мәктәбе (Кукмара районы)	
37	Пәрәү урта мәктәбе (Лаеш районы)	2017
38	Салавыч урта мәктәбе (Балтач районы)	
39	Такталачык урта мәктәбе (Актаныш районы)	
40	Татарстан Республикасы халык мәгарифе музее (Казан шәһәре)	
41	*Ташкичү гомуми белем мәктәбе* (Арча районы)	2009
42	Тәрбия эшләре үзәге (Казан шәһәре Авиатөзелеш районы)	
43	Түбән Суыксу урта мәктәбе (Тукай районы)	
44	*Ундүртенче татар гимназиясе* (Бөгелмә шәһәре)	2009
45	Унҗиденче татар гимназиясе (Казан шәһәре Мәскәү районы)	
46	Унсигезенче гимназия (Казан шәһәре Идел буе районы)	
47	*Унынчы гимназия* (Яшел Үзән шәһәре)	2014
48	«Шатлык» балалар бакчасы (Саба районы)	
49	«*Шатлык*» балалар бакчасы (Чаллы шәһәре)	2014

Кушымта 2

КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ КУЛЪЯЗМА ХЕЗМӘТЛӘРЕ ҺӘМ АҢА НИСБӘТЛЕ МАТЕРИАЛЛАР

КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
Н.И. ЛОБАЧЕВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФӘННИ КИТАПХАНӘСЕНЕҢ
КУЛЪЯЗМАЛАР ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ ФОНДЫННАН

№ п/п	Кулъязма әсәрнең исеме	Форматы	Күләме
	Тел белеме буенча		
1	«Әнмүзәҗ» (Татар теле грамматикасы)	22×18	59 кәгазь
2	«Әнмүзәҗ»	18×22	82 кәгазь
3	«Кавагыйде лисане гарәб» (Гарәп теле грамматикасы)	22×18	18 кәгазь
4	«Ләһҗәи татари» (Татар теленең тулы аңлатмалы сүзлеге)	18×22	201 кәгазь
5	«Нәмүнә яки әнмүзәҗ» (Рус теленең сарыф вә нәхү кагыйдәләре бәянында)	22×18	150 кәгазь
	Матур әдәбият		
6	«Җәваһир әл-хикаять» (Хикәяләрнең җәүһәре)	22×17	98 кәгазь
7	«Көнчыгыш романнарыннан»	22×18	76 кәгазь
8	«Кырык вәзир»	18×22	8 кәгазь
9	«Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимеше)	22×18	238 кәгазь
10	«Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият»	18×22	280 кәгазь
	Тарихи һәм дини темага караган язмалар		
11	«Археология материаллары»	22×18	65 кәгазь
12	«Ислам дине вәкилләренең биографиясе»	22×18	10 кәгазь
13	«Истәлекләр»	22×36	2 кәгазь
14	«Казан тарихыннан»	22×18	14 кәгазь
15	«Каюм Насыйри шәҗәрәсе»	–	2 зур кәгазь
16	«Мифтах әл-Коръән»	22×18	212 кәгазь
17	«Мохтасар тәварихы әнбия» (Пәйгамбәрләрнең кыскача тарихы)	22×18	2 кәгазь
18	«Мохтасар тәварихы әнбия»	22×18	11 кәгазь
19	«Мохтасар тәварихы әнбия»	22×18	30 кәгазь
20	«Некролог яки кыскача сиярь»	18×22	27 кәгазь
21	«Пәйгамбәрләр шәҗәрәсе»	34×22	7 кәгазь
22	«Тәварихы Казан»	22×18	14 кәгазь
23	«Төрле вәгазьләр»	18×22	10 кәгазь

№ п/п	Кулъязма әсәрнең исеме	Форматы	Күләме
24	«Төрле темадагы кулъязмалар»	17×20	89 кәгазь
25	«Төрле темадагы кулъязмалар»	17×20	113 кәгазь
26	«Төрле шәҗәрәләр»	22×34	17 кәгазь
27	«Утыз вәгазь»	18×22	15 кәгазь (гарәп телендә)
28	«Һәртөрле язмалар»	22×18	129 кәгазь
29	«Әсатыйр әл-әүвәлин»	22×18	4 кәгазь
Анатомия, арифметика, ботаника, география, тел белеме, ашау-эчү һәм башка темага караган язмалар			
30	«Аусафы җәзирәт әл-гарәб» (Гарәбстан географиясе)	18×22	108 кәгазь
31	«География материаллары»	22×18	38 кәгазь
32	«География материаллары»	22×18	127 кәгазь
33	«Гөлзар вә чәмәнзар» (Үләннәр һәм чәчәкләр)	17×22	34 кәгазь
34	«Гөлзар вә чәмәнзар»	18×22	114 кәгазь
35	«Гөлзар вә чәмәнзар»	18×22	116 кәгазь
36	«Гөлзар вә чәмәнзар»	18×22	77 кәгазь
37	«Лөгате нәбатәт» (Үлән һәм чәчәкләрнең исемнәре)	12×22	32 кәгазь
38	«Лөгате нәбатәт»	22×18	51 кәгазь
39	«Лөгате нәбатәт»	18×22	68 кәгазь
40	«Җәгърафияи кәбир» (Олы география)	18×30	130 кәгазь
41	«Иршад әл-әтбига» (Төрле аш әзерләү юллары)	18×22	28 кәгазь
42	«Истыйлахаты җәгърәфия» (География терминнары)	18×22	51 кәгазь
43	«Йорт өчен йимеш киптермәк вә аннан мөраббә хәзерләмәк»	18×22	2 кәгазь
44	«Мәнафигы әгъза вә кануны сыйхәт» (Кешенең анатомиясе, физиологиясе һәм сәламәтлекне саклау кагыйдәләре)	18×22	51 кәгазь
45	«Мәнафигы әгъза вә кануны сыйхәт»	18×22	38 кәгазь
46	«Санаигы голфания» (Гальваник электр тогы ярдәмендә кыйммәтле металлар белән йөгертү ысулы турында китап)	18×22	34 кәгазь
47	«Хисаплык» (Арифметика)	18×22	86 кәгазь

№ п/п	Кулъязма әсәрнең исеме	Форматы	Күләме
Календарьлар			
48.	«Календарь материалы – 1875 ел өчен»	18×22	19 кәгазь
49.	«Календарь материалы – 1880 ел өчен»	24×15	25 кәгазь
50.	«Календарь материалы – 1885 ел өчен»	22×17	30 кәгазь
51.	«Календарь материалы – 1889 ел өчен»	18×22	29 кәгазь
52.	«Календарь материалы – 1894 ел өчен»	22×17	29 кәгазь
53.	«Календарь материалы – 1897 ел өчен»	18×22	29 кәгазь
Төрле эчтәлекле язмалар			
54.	«Төрле таркау кәгазьләр»	22×18	54 кәгазь
55.	«Төрле таркау кәгазьләр»	18×22	89 кәгазь
56.	«Төрле таркау кәгазьләр»	22×18	209кәгазь
57.	«Төрле таркау кәгазьләр»	17×22	29 кәгазь
58.	«Төрле таркау кәгазьләр»	18×22	20 кәгазь
59.	«Төрле таркау кәгазьләр»	18×22	14 кәгазь
60.	«Төрле таркау кәгазьләр»	18×22	34 кәгазь
61.	«Төрле таркау кәгазьләр»	22×18	24 кәгазь
Төрле хатлар			
62.	«Габделвәлинең абыйсы Каюм Насыйрига язган хатлары»	–	8 данә
63.	«Габделвәлинең аталарына язган хатлары»	–	13 данә
64.	«Габделганинең абыйсы Каюм Насыйрига язган хатлары»	–	3 данә
65.	«Габделганинең аталарына язган хатлары»	–	9 данә
66.	«Габделкавиның абыйсы Каюм Насыйрига язган хатлары»	–	12 данә
67.	«Габделкавиның ата-анасына язган хатлары»	–	5 данә
68.	«Габделкавига кардәшләреннән килгән хатлар»	–	8 данә
69.	«Габденнасыйр мулланың улы Каюмга язган хатлары»	–	31 данә
70.	«Габденнасыйр мулланың улларына язган хатлары»	–	15 данә
71.	«Габделхәй Казанскийның атасына язган хатлары»	–	38 данә
72.	«Габделхәй Казанскийның әнесе Каюм Насыйрига язган хатлары (1858–1872)»	–	39 данә
73.	«Каюм Насыйри архивыннан табылган төрле кешеләрнең хатлары»	–	9 данә

№ п/п	Кулъязма әсәрнең исеме	Форматы	Күләме
74.	«Каюм Насыйриның ата-аналарына язган хатлары»	–	14 данә
75.	«Каюм Насыйриның атасы Габденнасыйр мулланың хатынына язган хатлары»	–	8 данә
76.	«Каюм Насыйриның карендәшләренә язган хатлары»	–	9 данә
77.	«Каюм Насыйрига кардәшләреннән килгән хатлар»	–	16 данә
78.	«Каюм Насыйри карендәшләренең үзара язышкан хатлары»	–	18 данә
79.	«Каюм Насыйрига килгән төрле хат һәм язмалар»	–	48 данә
80.	«Каюм Насыйрига килгән чакыру хатлары һәм төрле язмалар»	–	25 данә
81.	«Каюм Насыйриның төрле кешеләргә язган хатлары»	–	6 данә
82.	«Каюм Насыйриның төрле кешеләргә язган хатлары»	–	12 данә
83.	«Килгән хатларның конвертлары»	–	8 данә
84.	«Мәхкәмия исламия исеменә гариза»	–	1 данә

№ п/п	**Бастырылган әсәрнең исеме**
	Тел белеме буенча
1.	Насыйри К. Нәмүнә яки әнмүзәҗ. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1891. 184 б.
2.	Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1895. 87 б.
3.	Насыйри К. Ләһҗәи татари. I җилд. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1895. 226 б.
4.	Насыйри К. Ләһҗәи татари. II җилд. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1896. 106 б.
5.	Насыйри К. Кавагыйде лисане гарәб. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1896. 74 б.
	Ботаника
6.	Насыйри К. Гөлзар вә чәмәнзар ягъни үләнлек вә чәчәклек. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1894. 112 б.
7.	Насыйри К. Гөлзар вә чәмәнзар ягъни үләнлек вә чәчәклек. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1903. 112 б.

	Матур әдәбият
8.	Насыйри К. Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1884. 615 б.
9.	Насыйри К. Җәваһир әл-хикаять. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1898. 136 б.
	Тарихи темага караган хезмәтләр
10.	Насыйри К. Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Казан: Татиздат, 1926. 19–20 б.
11.	Насыйри К. Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Казан: Татиздат, 1926. 9–18 б.
	География буенча китаплар. Анатомия буенча мәкалә
12.	Насыйри К. Осуле җәгърәфияи кәбир (Азия кыйтгасы). Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1894. 206 б.
13.	Насыйри К. Осуле җәгърәфияи кәбир (Африка кыйтгасы). Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1898. 200 б.
14.	Насыйри К. Осуле җәгърәфияи кәбир (Гарәбстан, Шам, Гыйрак мәмләкәтләре хакында). Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1899. 138 б.
15.	Насыйри К. Мәнафигы әгъза вә кануны сыйхәт. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1893. 46 б.
	Календарьлар
16.	Насыйри К. Казан календаре. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1875. 59 б.
17.	Насыйри К. Казан календаре. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1879. 49 б.
18.	Насыйри К. Казан календаре. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1884. 59 б.
18.	Насыйри К. Казан календаре. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1888. 46 б.
19.	Насыйри К. Казан календаре. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1896. 40 б.
	Дин
20.	Насыйри К. Утыз вәгазь. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1887. 187 б.
21.	Насыйри К. Утыз вәгазь. Казан: Казан университеты тибгыханәсе, 1904. 187 б.

Кушымта 3

ТР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНЫҢ ЯЗМА МИРАС ҮЗӘГЕ ФОНДЫННАН КАЮМ НАСЫЙРИ ХАКЫНДА МАТЕРИАЛЛАР

Опись №1 рукописей К. Насыри и их фотокопий за 1861–1893 гг.

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
1.	Краткий список трудов Каюма Насыри составлен автором на русском языке и озаглавлен: «Фактическое доказательство знания дела»	1872 г.	1
2.	То же, фотокопии	1872 г.	2
3.	То же, фотокопии	1872 г.	2
4.	«Казанский календарь». Настольный календарь 1871 г., за №I, издаваемый К.Насыри. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите с исправлениями и наметками автора. На I листе есть подпись цензора И.Ф. Готвальда от 16 ноября 1870 г. о дозволении печатать. Подлинник. Напечатано: Казань. 1971 г.	1871 г.	45
5.	Материалы к «Казанскому календарю» 1872 г., издаваемому К.Насыри, рукописные разрозненные листы на татарском языке, арабском алфавите	1872 г.	10
6.	«Русско-татарский словарь». Рукопись на русском и татарском языках. Подлинник		57
7.	Неполный экземпляр «Русско-татарского словаря». Рукопись на русском и татарском языках. Подлинник		13
7а.	«Краткая татарская грамматика», ч. I. Напечатано: Казань, 1860 г.	1860 г.	4
8.	Отрывок из «Русско-татарского словаря». Рукопись на татарском и русском языках. Подлинник	1860 г.	31
9.	Неполный вариант «Татарско-русского словаря». Подлинник. По нумерации автора отсутствуют лл. 1, 2, 3, 7, 8, 15, 16. Нет конца. Подлинник. Напечатано: Казань. 1875 г. 120 стр.	1875 г.	29
10.	Разрозненные листы черновых записей по татарско-русскому словарю. Подлинник		34
11.	Отрывок из «Тюркско-татарско-русского словаря». Рукописный текст на татарском и русском языках. Подлинник		48
12.	Словарь русских слов одного корня. Рукопись на русском языке. Подлинник		22

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
13.	Отрывки из первого варианта «Учебника по арифметике». На первом титульном листе имеется резолюция: цензурою дозволено. Казань. 13 января 1873. Выданный цензором И.Ф.Готвальдом и рукопись автора на татарском языке, арабском алфавите с его правками. Подлинник. Напечатано: Казань. 1873 г. 52 стр.	1872 г.	10
14.	Титульный лист второго дополненного издания «Учебника по арифметике». Рукописный текст К.Насыри на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник. Напечатано: Казань. 1897 г. 85 стр.	1874 г.	I
15.	Объявления К.Насыри о продаже собственных изданий. Рукописный текст на татарском и русском языках. Подлинник	1876 г.	2
16.	То же, фотокопии		2
17.	То же, фотокопии		2
18.	Оттиск объявления о продаже книг, изданных К.Насыри. На татарском языке, арабском алфавите		1
19.	Прошения К.Насыри в Правление Казанской духовной семинарии о представлении отпуска с 15 июля 1864 г. по 1 сентября 1864 г. Рапорт инспектору татарских, башкирских и киргизских школ об утере талонов на получение жалования за декабрь 1872 г., январь, февраль 1873 г. Донесение о переводе долговой книги купца Ямашева с татарского на русский диалект.Рукописные тексты автора на русском языке. Подлинники	1864, 1872, 1873 гг.	5
20.	Термины по геометрии. Рукописный текст автора на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		4
21.	Наброски по физической географии. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		19
22.	Схема затмения солнца, выполненная К.Насыри на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		I
23.	То же, фотокопия		I
24.	То же, фотокопия		I
25.	Карта железной дороги России 1779–1880 гг., составлена К.Насыри на татарском языке. Подлинник	1879 г.	1
26.	Черновики географических карт, исполненные К.Насыри на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		2

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
27.	Заметки о правилах письма. Рукописный текст автора на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		6
28.	Наброски К.Насыри «по истории религий».Рукопись на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник	1876 г.	62
29.	Наброски К.Насыри по географии. Подлинник на татарском языке, арабском алфавите. На листе 83 – черновик заявления К.Насыри. На листе 84 заявление переписано, о чем научным сотрудником ИЯЛИ КФАН СССР сделана соответствующая отметка		84
30.	Отрывок из книги К.Насыри «О лечебных свойствах трав». Подлинник на татарском языке, арабском шрифте	1888 г.	11
30а.	«Дини хотбәләр»		1
31.	Насыри Каюм (Насыров Габделкаюм Габделнасырович) (1825–1902) – татарский ученый, просветитель. Рукописный текст автора на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		5
32.	Статья К.Насыри с требованиями о качественном печатании книг. Рукописный текст. Подлинник на татарском языке, арабском алфавите. Напечатано: г. Казань. «Календарь». 1883 г.	1883 г.	1
33.	То же, фотокопия 1883 г.		1
34.	То же, фотокопия 1883 г.		1
35.	Тетрадь-конспект по астрономии. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник	1893 г.	35
36.	Тетрадь-конспект по грамматике татарского языка. Рукопись на татарском и русском языках. Подлинник		27
37.	Образцы арабской каллиграфии К.Насыри. Подлинник		5
38.	То же, фотокопия		5
39.	То же, фотокопия		5
40.	Правила приема в гимназию. Рукопись К.Насыри на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		5
41.	Отчет преподавателя татарского языка К.Насыри в духовном училище за 1861/1862 учебный год и списки учеников данного училища. Подлинник на русском языке с подписью автора	1861–1862 гг.	6

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
42.	Финансовый отчет русской школы, для детей татар (за период с 1 января 1872 г. по 1 января 1873 г.), организованной по инициативе Каюма Насыри. Рукописный текст К.Насыри на русском языке. Подлинник	1873 г.	1
43.	Раздельные письма казанского мещанина Сулеймана Аитова и жены арского купца Халиды Бакировой о разделе имущества между детьми. Приговоры и донесения крестьян-татар Мало-Ширданского сельского общества, Свияжского уезда, Казанской губернии о перестройке соборной мечети. Подлинник. Рукописи К.Насыри на русском языке	1861–1874 гг.	6
44.	Альбом цветов и растений в красках, купленный Апанаевым Абдуллой Юсуфувичем в январе 1890 г. у Каюма Насыри. На некоторых листах есть пометки Каюма Насыри на татарском языке, арабском алфавите	1890 г.	120
45.	Памятная книжка с записями К.Насыри о продаже своих изданий. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник		33
46.	Разрозненные листы черновых записей К.Насыри. Рукописи на татарском и русской языках. Подлинники		64
47.	Фотокопия свидетельства на имя бывшего ученика духовной семинарии Эмель Эльхруна, выданного преподавателем татарского языка Казанской русской семинарии К.Насыри, о его учебе в духовной семинарии. Рукописный текст на татарском языке, арабском алфавите	1868 г. 8 апреля	1
48.	Фотокопии рукописей Каюма Насыри на татарском языке, арабском алфавите	1874, 1877 гг.	6
49.	Фотокопии рукописей Каюма Насыри на русском языке		7
50.	Насыри Каюм. Карта государственных границ России. Показаны: реки, моря, населенные пункты, границы. Бумага писчая, наклеенная на оберточную синюю бумагу. В I краски. 33 × 23,5 / 35,5 × 25,5/. На татарском языке, арабский шрифт. 1878 г. 23 июля	1878 г.	1
51.	Насыри Каюм. Заметки о значении учебника по арифметике. Рукопись на татарском языке, арабский алфавит		2

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
52.	Насыри Каюм. Отрывок из книги «Зеркало жизни и поминание обыкновений». Рукопись на татарском языке, арабский алфавит. 1861 г.	1861 г.	3
53.	Насыри Каюм. Об истории школы, в которой впервые будет преподавать русский язык. Рукопись. На татарском языке, арабский алфавит. 1876 г.	1876 г.	7
54.	Насыри Каюм. Тетрадь с некоторыми записями о приходе и расходах автора. Рукопись на татарском языке, арабский алфавит	1901 г.	3
55.	Насыри Каюм. Заметки, наброски по интересующим автора вопросам. Разрозненные листы, на татарском языке, арабский алфавит		9

Опись № 2 писем К.Насыри за 1840–1894 гг.

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
1.	Письма К.Насыри отцу Хусаинову Габделнасыру Хусаиновичу. Рукописный текст на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 10 писем. Подлинники	1848 г., 1862 г. 10 октября	11
2.	То же, фотокопии		12
3.	То же, фотокопии		12
4.	Письма брату Казанскому Габделхаю Насыровичу из Казани. Рукописный текст на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 3 письма. Подлинники	1865 г. 9 мая 1887 г. 8 июля	4
5.	То же, фотокопии		7
6.	То же, фотокопии		7
7.	То же, фотокопии		7
8.	Письма К.Насыри матери, братьям и родным. Подлинники на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 4 письма	1859 г. 29 октября, 1874 г. 21 июня, 1884 г. 24 октября	5
9.	То же, фотокопии		8
10.	То же, фотокопии		8
11.	То же, фотокопии		8

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
12.	Записки Каюма Насыри неустановленным лицам и без дат. На татарском языке, арабском алфавите, большинство за подписью автора, 9 записок. Подлинники		9
13.	Хусаинов Габделнасыр Хусаинович – отец К.Насыри. Письма Каюму Насыри. Подлинники на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 15 писем	1841 г. 15 мая, 1864 г.	19
14.	Насыров Габделхай Габделнасырович (Казанский Г.) – брат К.Насыри. Письма Каюму Насыри. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 33 письма. Подлинники	1840 г. 3 марта, 1897 г. 1 мая	40
15.	Насыров Габдулвали Габделнасырович – брат К.Насыри. Письма Каюму Насыри. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора. Подлинники	1854 г, декабрь 1855 г. 19 марта, 1859 г. 14 марта, 1893 г. 18 марта	8
16	Насыров Габдулгани Габделнасырович – брат К.Насыри. Письма Каюму Насыри. Рукописный текст на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 4 письма. Подлинники (Насыров Габдулгали Габделнасырый улы – брат К. Насыри. Каюм Насыри)	1852 г. 19 июля, 1865 г. 15 февраля	5
17.	Насыров Габделкаюм Габделнасырович – брат К.Насыри. Письма Каюму Насыри. Рукописный текст на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 3 письма. Подлинники	1866 г. 28 декабря, 1891 г. 20 июля, 1892 г. 7 марта	4
18.	Письма и записки родных Каюму Насыри. Подлинники на татарском языке, арабском алфавите. Дат и подписей авторов нет или неразборчивые, 8 писем		9

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
19.	Письма родных Каюму Насыри, расположенные в алфавитном порядке по фамилиям корреспондентов. Рукописи на татарском языке, написанные арабским алфавитом, 48 писем на 58 лл. Подлинники. Писем на русском языке – 3, на 4 лл. (лл.: 17–18, 26, 45). Писем на турецком языке – 1, на 2 лл. (лл.: 47–48). Итого: 52 письма	1844–1899 гг.	64
20.	Письма К.Насыри от неизвестных лиц / без дат и с неразборчивыми подписями. На татарском языке, арабском алфавите, 5 писем. Подлинники		7
21.	Хусаинов Габделнасыр Хусаинович – отец К.Насыри. Письма отца К.Насыри сыновьям: Габделхаю, Габдулвали, Габдулгани, Габдулкаюму. Подлинники на татарском языке, арабском алфавите, 4 письма	1848 г. 12 февраля, 1850, 1859, 1864 гг.	7
22.	Насыров Габделхай Габделнасырович (Казанский Г.Г.) – брат К.Насыри. Письма отцу – Хусаинову Габделнасыру Хусаиновичу. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора, 4 письма. Подлинники	1850 г. 24 января, 31 марта, 11 апреля, 1870 г. 7 июля	4
23.	Насыров Габделхай Габделнасырович (Казанский Г.) Письмо Каюму Насыри. На татарском языке, арабский алфавит. Подлинник		1

Опись №3 материалов к биографии К.Насыри за 1816–1899 гг.

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
1.	Паспортная книжка (Габдулнасырова Абдулкаюма) за №1197, выданная Ширданским волостным старшиною, Свияжского уезда, Казанской губернии. С пометами неизвестного лица дат рождения и смерти К.Насыри – на татарском языке. Подлинник	1898 г. 22 июня	8
2.	То же, фотокопии		5
3.	Насыри Каюм. «Шәҗәрә» («Родословная») о поколении Насыровых. Родословная дана в виде разветвленного дерева. Подлинник. Рисунок К.Насыри. Издан в 1880 г.	1880 г.	1
4.	То же, черновые варианты. Подлинники		4
5.	То же, фотокопия		1

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
6.	Насыри Каюм. Фотокопия билета, выданного Правлением Казанской духовной семинарии Каюму Насырову с правом выезда на Родину – в дер. Ширданы Свияжского уезда Казанской губернии, сроком с 19 июля 1857 г. по 1 августа 1857 г.	1857 г. 19 июля	1
7.	Фотокопии: 1. Дом в д. Ширдан, в котором родился К.Насыри 2. Здание Ширданского сельского Совета 3. Групповое и отдельное фото родственников К.Насыри		4
8.	Фотографии зданий г. Казани, связанных с жизнью и деятельностью К.Насыри		6
9.	Пригласительные билеты на заседания члену Общества истории и этнографии Каюму Насырову. Адрес написан секретарем общества Н.Катановым. 3 билета	1894 г. 28 ноября, 1899 г. 11 мая	3
10.	Пригласительные билеты, адресованные Каюму Насыри. Рукописный текст на татарском языке, арабском алфавите, 6 билетов. Подлинники	1887, 1891–1892, 1897–1898 гг.	6
11.	Фотокопии билетов из Петербургского цензурного комитета за №8255 – на издание книги К.Насыри на татарском языке «Эльмузяж» («Грамматика»); за №7495 – «Джеватруль хикяите» («Первые рассказы»)	1894 г. 26 декабря, 1895 г. 2 декабря	2
12.	Переписка К.Насыри с Петербургским цензурным комитетом, с типографией Казанского университета, с редакцией газеты «Переводчик» (г. Бахчисарай) и т.д. об издательстве своих трудов	1868 г. 13 февраля, 1871 г. 14 мая, 1886 г. 29 апреля, 1895 г. 24 августа	6
13.	То же, фотокопии		10
14.	То же, фотокопии		10
15.	Хусаинов Абдульнасыр – отец Каюма Насыри. Фотокопия годичного паспорта отца К.Насыри – Хусаинова Абдулнасыра, выдан Свияжским уездным Казначейством Казанской губернии на срок с 19 июня 1816 г. по 9 июля 1817 г.	1816 г. 19 июля	1

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
16.	Насыри Каюм «Шәҗәрә» («Родословная») о поколении Насыровых. Написана на рисунке разветвленного дерева на татарском языке, арабский алфавит. Издано в 1880 г.	1880 г.	1
17.	Насыри Каюм. Завещание. На татарском языке, арабский шрифт, с подписью и именной печатью автора – 13 октября 1901 г. Подлинник	1901 г.	1
18.	Насыри Каюм. Завещание, написанное со слов автора на татарском языке муллой д. Альман Габдулкави Абдулнасыровым. 9 апреля 1902 г. Перевел на русский язык губернский секретарь Ибниамин Юсупович Арсеев 7 мая 1902 г. Подлинник на русском и татарском языках, арабский шрифт. Заверен нотариусом и печатью	1902 г.	2

Опись №4 воспоминаний, очерков, газетных вырезок о к.насыри, фотокопий титульных и отдельных листов из его произведений. Фотоиллюстрации к пьесе М.Гали и Уразикова К.Насыри. Прочая переписка об издании трудов К.Насыри

№ п/п	Заголовок единицы хранения	Крайние даты	Кол-во листов
1.	Алиши Хатип Әлмәти, татарский писатель, ученик К.Насыри. Воспоминания о Каюме Насыри. Подлинник. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора. Опубликовано: «Каюм Насыри» 1825–1945. (Материалы научной сессии, посвященной 120-летию со дня рождения). Казань: Татгосиздат, 1946. 141 с.	1945 г. 18 июля	2
2.	Бахтияров Вафа Галиевич, татарский журналист. Воспоминания о Каюме Насыри. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите с подписью автора. Подлинник	1945 г. 30 июля	13
3.	Усманов Хатип Усманович, аспирант Казанского педагогического института. «Каюм Насыри и фольклор». Очерк на татарском языке. Машинописная копия с авторской правкой и добавлениями.	1941 г.	67
4.	Хисматуллин Абдулхай Хисматуллович, старший научный сотрудник Тат. НИЯЛИ. Заключение к очерку Х.Усманова «Каюм Насыри и фольклор». Машинописная копия с авторской правкой и подписью	1941 г. 31 июля	1

5.	Ярмухаметов Хамид Хуснутдинович (Ярми Х.Х.), старший научный сотрудник Тат. НИЯЛИ. Об очерке Х.Усманова «Каюм Насыри и фольклор». Речь Х.Ярми 5 сентября 1941 г. на заседании ученого совета Татарского научно-исследовательского института языка, литературы и истории. Машинописная копия на татарском языке с подписью автора	1941 г. 5 сентября	4
6.	Насыров Габделбари Габделхаевич – 1881 года рождения, переплетчик Казанского промполиграфа. Воспоминания о Каюме Насырове. Записал со слов Насырова Г.Г. младший научный сотрудник Тат. НИЯЛИ М.Гали (Мухаммет Галеев). Рукопись на татарском языке, арабском алфавите, с подписью М.Гали. Опубликовано: «Каюм Насыри» 1825–1945. (Материалы научной сессии, посвященной 120-летию со дня рождения). Казань: Татгосиздат, 1948. 139 с.	1945 г. 10 марта	1
7.	Укмаси Миргазиз. «Уважаемый Каюм Насыров». Воспоминания о Каюме Насыри. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите. Подлинник. Напечатано: журнал «Совет әдәбияты». 1945. №2. Казань		4
8.	Фотографии стендов, фотовыставки произведений Каюма Насыри, посвященной столетию со дня рождения (1825–1925 гг.). 3 фото	1925 г. 15 февраля	3
9.	Пригласительные билеты на научную сессию, посвященную 120-летию (1825–1945) со дня рождения выдающего татарского ученого-просветителя, педагога Каюма Насыри. 37 билетов	1945 г. 17–19 марта	74
10.	Газетные вырезки за 1945 г., статьи и информация о 120-летии со дня рождения Каюма Насыри. Среди них: 1. Гайнуллин М. – кандидат филологических наук. «Выдающийся татарский ученый и писатель Каюм Насыров». «Красная Татария», 7 января; 2. Горохов В. – доцент. «Великий татарский ученый Каюм Насыри». «Кызыл Татарстан», 7 января; 3. Рамазанов Ш. «Основоположник современного татарского литературного языка». «Кызыл Татарстан», 21 февраля	1945 г. 7 февраля, 1 апреля	11 2 4 7
11.	Каюм Насыри. Фотокопии отдельных листов из произведений К.Насыри (Календарей 1871, 1879 гг. Большая география – 1898 г.). 5 фото размером 13,4 × 17,8	1871, 1879, 1898 гг.	5

12.	Шамиль Касим – артист Татарского академического театра. Биография Каюма Насыри с приложением списка его научных трудов. Машинописная копия с подписью автора	1940 г. 23 мая	50
13.	Шамиль Касим – артист Татарского академического театра. Материалы о Каюме Насыри (список его произведений. Русские ученые о Каюме Насыри). Машинописная копия на татарском языке, экз. №1	1940 г. 23 мая	9
14.	То же, экз. №2		9
15.	То же, экз. №3		9
16.	Насыри Каюм. Фотокопии титульных листов произведений Каюма Насыри: «Календари», «Книга для собеседников по литературе», «Терминология по географии», «Грамматика», «Толковый словарь татарского языка», «Авиценна» и др.	1879, 1884, 1890, 1892, 1894–1895, 1906 гг.	17
17.	Галеев Мухамет, младший научный сотрудник Тат. НИИЯЛИ; Уразиков, Татарского академического театра, фотоиллюстрации к пьесе М.Гали (Галеева Мухаммета) и Уразикова «Каюм Насыри». Размеры 11,5 × 17,5. 12 фото	1945 г.	12
18.	Масловский Пётр, крупный специалист татарского языка (бывший учащийся К.Насыри в Казанской духовной семинарии). Наброски по всеобщей истории, написанной автором для издаваемого «Календаря К.Насыри». Рукописный текст на русском языке с частичным переводом на татарский язык и подписью автора		14
19.	Шамсуаров Шамсетдин, учитель Каюма Насыри. Фотокопии письма (1) учителя Каюма Насыри Шамсетдина Шамсуарова, а также фотокопия рукописи из его книги: начала (1 рис.) и конца (2 рис.). 3-й рисунок – фотокопии печати К.Насыри. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите	1925 г. 20 ноября	2
20.	Пригласительный билет на свадьбу на имя Марджани Шигаба. Рукопись на татарском языке, арабском алфавите	1888 г. 25 сентября	1
21.	Насыри Каюм – предварительные сведения о татарском языке, письме в чтении. [Запись по грамматике ученика духовного училища]. Рукопись на русском языке		4

АББРЕВИАТУРАЛАР

АССР – Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ВКП(б) – Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе (Всесоюзная коммунистическая партия (большевиков))
ҖЧҖ – җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять
КПСС – Советлар Союзы коммунистлар партиясе (Коммунистическая партия Советского Союза)
РКП(б) – Россия коммунистлар (большевиклар) партиясе (Российская коммунистическая партия (большевиков))
РСФСР – Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы
РФ – Россия Федерациясе
СССР – Совет Социалистик Республикалар Союзы
ТАССР – Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ТР – Татарстан Республикасы.

АВТОРЛАР ИСЕМЛЕГЕ

Л.М.Айнетдинова, Л.Р.Әскәрова, Ф.Р.Бәдретдинова, Р.М.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Г.М.Габделхакова, Э.М.Галимова, Д.М.Галиуллина, Д.М.Госманова, Ф.С.Гыйниятуллина, Г.Р.Давлетьянова, Д.Ф.Заһидуллина, М.Е.Ильина, Р.Ф.Исламов, Ф.Г.Камальтдинова, Г.И.Каюмова, Ф.Г.Кәлимуллина, Ф.Г.Миңнеханов, Р.М.Мөхәммәтшин, А.Б.Насибуллина, Р.Р.Сәләхиев, И.Х.Хәлиуллин, Д.А.Шаһавиев, Р.В.Шәйдуллин, Ә.Ш.Юсупова.

ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ

Күрсәткечтә, битләре билгеләнеп, китапта искә алынган исем-фамилияләр кертелде. Аерым мәкаләләр багышланган шәхесләрнең фамилияләре курсив белән җыелды. Фамилияләр һәм инициаллар тәңгәлләшкән очракта исемнәр тулысынча бирелде яки дефинициялəр өстәлде.

Абдуллин Ибраһим Г. 207, 237
Абдуллин Искәндәр Г. 24, 27, 103
Абдуллин Мортаза 400
Абдуллин Я.Г. 28, 63, 102, 323, 375
Абдуллина Д.Г. 256
Абзалина Г.Ә. 340
Абзалина Р.Ә. 49, 341
Абызов Н. 132
Абызов Ш. 248
Абызова Р.Р. 355
Агафонов Н.Я. 46
Аги А. 300
Агиев Ф. 297
Агишев Я.Х. 247
Адылов Н.И. 29, 52, 265, 354
Аити С. 300
Аитов М.С. 30, 31, 35, 47, 133
Аитов С.М. 30, 31, 178, 179, 247, 344, 409, 453
Аитова Ф. 31
Акаев Ә.А. 20, 32, 33, 34, 103, 257
Акашина Н.М. 33
Акбиев С.Х. 24, 33, 63, 103, 257, 375
Акмулла 113
Аксак Каратун, шул ук — Лука Конашевич
Аксёнова И.А. 49
Акчура Й. 452, 467
Акчурин А.К. 34, 69, 179, 215, 390, 453
Акчурина М. 109
Акъегетзадә М. 109, 301
Александр III 207, 210
Александров А.И. 136
Алиш А. 143, 198
Алишев С.Х. 24, 31, 35, 36, 103, 186, 233, 257
Алишев Х. 36
Алкин Н.С. 265
Алкин С.Ш. 216
Алкин Ш.С. 36, 256
Алпаров Г. 128

Амашев Ф. 382
Анастасиев А.И. 215
Апанаевлар 200
Аппакова Д. 464
Аретьев И.Й. 94
Аристотель 241
Арслан М. 300
Арсланов Г.В. 40, 59, 62, 174, 198, 353
Арсланов И. 31
Арсланова Р.М. 41
Артур 328
Архангельский А.С. 48
Атласи Һ. 47, 397
Атнагулов С. 122, 132, 167
Ахун С.С. 29, 52, 354, 384
Ахунов Г. 156
Әбдери мулла 45
Әбу Гали Хөсәен ибне Габдуллаһ 55
Әбу Җәгъфәр Мөхәммәд бине Җәрир әт-Табари 289
Әбугалисина 242
Әбү Сәед казый 291
Әбүзәров Х. 83, 184, 185
Әгъләм М. 448
Әйбәтов Х. 214
Әлминов Б.М. 174, 186, 244, 354, 375, 384
Әлмөхәммәт 9, 303, 325
Әминә 328
Әмир М. 336
Әмирхан Ф.М. 21, 23, 40, 56, 57, 59, 61, 62, 68, 83, 116, 132, 171, 174, 202, 252, 297, 314, 323, 336, 353, 382, 391, 400, 412, 464
Әмирханов Р.М. 24, 62, 104
Әмрә Юныс 465
Әпсәләмовлар 200
Әсәдуллин А.Ш. 64, 103, 375
Әхмәд бине Ильяс 194
Әхмәд ибне Фазлан 100
Әхмәд мулла 264
Әхмәдиев Ш.Г. 23, 67, 132, 174, 375
Әхмәдуллин А.Г. 68
Әхмәров Г.Н. 47, 457, 458
Әхмәров Ш.И. 35, 68, 179, 215, 216, 390
Әхмәт Абдулла 198
Әхмәт Рәфыйк 276
Әхмәт хәзрәт 340
Әхмәтгалиева Я.С. 24, 69, 78, 103
Әхмәтҗанов М.И. 465
Әхмәтҗанова Г.М. 423
Әхмәтов И.К. 330
Әхмәтова Фазыйлә 325
Әхтәмов И. 75
Бабич Ш. 116, 279
Баембитов Г.С. 23, 71, 252
Байбакты 303
Бакиев М.К. 257
Балан Ш. 182, 203
Баласагуни Й. 289
Балинт Г. 313, 339
Бариев И.Г. 328, 330
Бариев Т.Ф. 330
Бариев Ф.Г. 328
Бариева Бәрра 327, 328
Бариева Е.И. 330
Бартольд В.В. 126
Баруди Г. 94, 115, 202, 226, 283, 297, 324, 381, 395, 408
Басыйров З.И. 354
Баттал Г.Г. 22, 57, 74, 75
Батулла Р. 448
Батырморзаев Н. 34
Батырша 147, 381
Батыршина Г.Г. 24, 76, 254, 355
Бах Р.Р. 52
Баһаветдинова Д.Б. 24, 77, 104, 384
Баһадур Ә. 364
Баһманов И. 232
Баязитов Г. 69, 78
Баязитов И. 326
Баязитов М. 78
Бәдигъ мөәзин, шул ук — Хөсәенов М.М.
Бәдигый Х.Г. 23, 79, 268
Бәкер К. 452
Бәхтияр әл-Мәмдәли хәзрәт 84
Бәхтияров В.Г. 83, 184, 185, 248, 464
Бәхтияров З.Г. 84, 185, 186, 233, 257, 300
Бәчек 44
Бәшири З. 452, 464
Бәширов Г. 149, 464
Бейбулатов Т. 34
Белинский В.Г. 269
Березин И.Н. 126, 294, 387, 457, 458
Беркутов В.М. 24, 86, 375
Бибиҗәдирә 326
Бибиҗәзилә 326, 327
Бибиҗәмилә 325, 326
Бибикәримә 326
Бигиев Заһир 109, 322
Бигиев М. 105, 202, 452
Биккиниев Ш.С. 87, 212
Бикмуллин Х. 265
Бираш 9
Богородицкий В.А. 128, 215, 387, 464
Бодуэн де Куртенэ И.А. 46
Болгари Х. 300
Борнаш 45
Борһанова Р.Г. 87
Борындык 45
Брюс Я.В. 212
Буби Габдулла 297
Буби Гобәйдулла 297
Будде Е.Ф. 136
Бурнаш Ф. 68, 464
Бусыри Ш. 464
Бутлеров А.М. 313
Вагыйзов С.Г. 91, 98
Вакыйф З. 372
Вамбери Х. 313
Васильев А.В. 215
Васильев М.А. 215
Вахиди С. 395, 464
Вахит мулла 45
Вахит Х. 68
Вахитов М. 166
Вахитов Р.М. 95, 354
Баһапов Г. 14, 339
Вәзиева Ж.Г. 23, 72, 74, 96, 233, 257, 375
Вәисов Б. 381
Вәкил 302, 303

Вәли бай 247
Вәли Я. 452
Вәлиди Ә. 425
Вәлиди Ж. 23, 57, 70, 96, 128, 202, 452
Вәлиев М.Ф. 102
Вәлиев Р.М. 49
Вәлиев Х. 132
Вәлиева-Сөләйманова Г.Ф. 52
Вәлитова Р.Г. 91, 98
Вәлиулла 303
Вәлиуллин М.Ә. 99
Вәлиуллин Ф.Р. 99, 354
Веселовский Н.И. 126
Вечеслав Г.М. 140
Вильк 125
Воробьёв Н.И. 23, 100, 232, 233, 257, 458, 459
Воронков М. 53
Высоцкий Н.Ф. 42, 46
Габәши С. 464
Габбас 44
Габделбарый 332
Габделвәли 325, 327, 454
Габделгазиз 454
Габделгани 325, 327
Габделганиева М.Х. 105
Габделгаффар 454
Габделкави 43, 94, 186, 264, 266, 325, 327, 330, 332, 401, 441
Габделкави мулла 93, 303, 330
Габделмән (Габделмән Казанский) 94, 179, 184, 245, 247, 248, 326, 344, 335, 385, 430
Габделнасыйров Габделкави Насыйри улы 197, 302, 330
Габделхәй 174, 245, 247, 255, 264, 325, 326, 327, 344, 385, 442, 465
Габдерәзак баба 229
Габдеррәзак 44
Габдессаттар 454
Габдессәләм мулла 264
Габдрахман (Бәрра ире) 328
Габдулла бине Яхъя 454
Габдулла мулла 45
Габдуллин Г.Г. 105
Габдуллин И.Г. 54
Габдүш Х. 300
Габидуллин Х.З. 23, 67, 106, 132
Гази И. 336
Газизов Р. 268
Гайнетдинов М.В. 24, 63, 102, 108, 367, 368, 431
Гайни мулла 44
Гайнуллин М.Х. 20, 23, 24, 60, 102, 109, 174, 232, 233, 254, 256, 257, 354, 366, 367, 375
Гайса 454
Гайсин Т. 110, 185, 233, 257, 263, 265, 468
Гайфуллин В.Г. 111, 112
Гали Г. 198, 297
Гали ибне Әбуталиб 464
Гали М. 23, 24, 60, 66, 84, 113, 114, 185, 202, 230, 233, 250, 256, 257, 332, 366, 375, 464
Галиев Габдрахман 115
Галиев М.И. 115, 216
Галиев Ш. 156, 422
Галиева Л.И. 115
Галикәев М.М. 216
Галимова Р.Ф. 330
Галиулла мулла 327
Ганиев Ф.Ә. 278
Ганиева Р.К. 24, 116, 266
Гариф Н.Г. 117
Гариф хәзрәт 300
Гаспралы Исмәгыйль 191
Гаспринский Исмәгыйль 147, 283
Гасыймов О.Р. 49
Гаташ Р. 116
Гатиятуллина Р.Ә. 50, 118
Гаттар Ф. 464
Гафури М. 113, 171, 279, 297, 314, 323, 382, 417, 463
Гаяз 454
Георги И.И. 457
Герасимов С.В. 400
Гибай, Себер бае 326
Гиганов И.И. 70, 127, 387
Гобәйдуллин Г.С. 23, 121, 122, 132, 167, 252
Гобәйдуллина А.Н. 25, 123, 229, 265, 266, 330
Гобәйдуллина М. 121
Гобәйдуллина Ф. 265
Гомәр шәех 220
Гомәров И.Г. 465
Гомәрова Г.М. 440
Горецкий В. 125
Горохов В.М. 23, 123, 124, 257
Готвальд И.Ф. 16, 22, 42, 85, 124, 126, 202, 249, 272, 291, 359, 379
Гоцци К. 40
Гөлнар ханым (Лебедева О.С.) 17, 195, 297, 359
Григорьев В.В. 12, 15, 21, 22, 43, 56, 85, 128, 297, 311, 313, 345, 411, 455
Гужавин М.М. 281
Гусев А.Ф. 136
Гыйбатдинов М.М. 355
Гыйззәт Тажи 68
Гыйззәтулла А. 300
Гыйззәтуллин Х.В. 31
Гыйланшаһ, Кейкавусның улы һәм варисы 194
Гыйләҗев Аяз 448, 469
Гыйльман Ф. 300
Гыймади Х.Г. 23, 42, 133, 233, 257
Гыймаев З.Ф. 99, 134, 354, 416
Гыйниятуллина Л.Ә. 423
Гыйрфанов Ф. 446
Гыйсмәти Г. 87
Гыйффәт Туташ 109
Даркшевич Л.О. 136
Даутовлар 200
Дәүләткилдиев И. 300, 318
Дәүләтшин Г.М. 463
Девятаев М.П. 143
Державин Г.Р. 41
Динмөхәммәт мулла 44

Динмөхәммәтов Ишмөхәммәт 395
Дмитриев Н.К. 21, 23, 39, 138, 139, 233, 257
Догель И.М. 136
Домбровский Б.Л. 140
Думави Н. 116
Дусаев Г. 141, 185, 233, 257, 263, 468
Дьюла Мессарош 80
Екатерина II 200, 246
Еники Ә. 336
Еникиева А.Р. 143, 144, 300, 412
Жуков Г. 198
Жумаева Ф.Р. 354
Җамалетдинова З.И. 145
Җамаш 45
Җами Габдерахман 464
Җәгъфәр мулла 264
Җәләй Л.Җ. 23, 24, 128, 149, 257, 366
Җәләлетдин Габдрахман ибне Әбүбәкер әс-Союти 85, 228
Җәләлиев Ш.Ш. 150, 376
Җәлил М. 33, 188, 198, 293, 317, 384, 464
Җиһанов Н. 174
Завьялов А. 244
Загоскин Н.П. 46, 48
Закир хәзрәт 182, 203
Закирова К.В. 153
Залеман К.Г. 22, 154
Залесский В.Ф. 136
Запольский И.И. 92
Зарипов И. 286, 373
Зарипов Э.Я. 155, 354
Заһидуллин И.К. 156
Зәйнуллин Г.Г. 157, 158, 195
Зәкиев М.З. 24, 63, 103, 128, 159, 387, 388
әз-Зәмәхшәри Габделкасыйм Мәхмүд ибне Гомәр 274
Зенцов Петр 188
Зийарид Кабус ибн Вушмгир 194
Зийаридлар 194
Знаменский П.В. 383
Зөһрә, К.Насыйриның хатыны 247
Зуев Е.В. 30
Зуева Т.А. 30
Зыяддин Сәед Яхъя 17
Зыязов Ф.Ә. 245
Зыятдинов Г. 232
Ибәтуллина М. 165, 185, 233, 257, 263, 264, 468
Ибраһим бай 232
Ибраһим бине Хуҗаш 202, 379
Ибраһим Я. 300
Ибраһимов Габдерәшит 382, 467
Ибраһимов Галимҗан Г. 21, 23, 33, 57, 70, 98, 116, 122, 128, 131, 132, 165, 166, 171, 174, 252, 269, 279, 293, 323, 375, 417, 425, 462, 464
Ибраһимова Ф.И. 24, 168, 178, 192, 261, 315, 395, 433, 437
Иван Калита 210
Иванов М.И. 127
Игъламов Н.Р. 329
Игъламова Н.М. 328, 329, 330
Игъламовлар 245
Ижукин И. 53
Износков И.А. 46
Илгиз 330
Илдар 328
Илдар Ш. 300
Ильминский Н.И. 22, 93, 202, 260, 287, 313, 383
Ильяси Г. 171
Имам Әгъзам (Ногман бине Сабит) 219
Имам Әхмәд 219
Имам Мәлик 219
Имам Шәфигъ 219
Иманаев М. 69
Иманкулов И. 115
Йосыпов Г. 400
Йосыф хәзрәт 248
Исай (Исәнгол) мулла 44
Исәнбаевлар 247
Исәнбәт Н. 23, 40, 59, 60, 62, 68, 132, 149, 173, 311
Исламов Р.Ф. 24, 175, 177, 178, 184, 233, 235, 254, 256, 465
Исламов Ф.Ф. 177
Исмәгыйль мулла 45
Исхаков В.М. 188
Исхаков Х. 31
Исхакова Ә. 446
Исхакова Р.М. 188
Исхакый Г.Г. 21, 22, 57, 68, 75, 97, 116, 122, 189, 202, 279, 300, 301, 318, 337, 383, 384, 467
Ишаев Н. 168, 179, 192, 453
Ишали 303
Ишбулат мулла 31
Ишимов Ядгәр (Шаһи Ядгәр) 247, 357
Ишморат Р. 68, 464
Ишнияз әл-Харәзми әл-Үргәнчи 371
Йосыф Ягъкуб улы 348
Кавиев Сәлим 330
Кавиев Х.С. 197, 198, 330, 354
Кавиева З.М. 330
Кавиева Ф.Ф. 330
Кавиевләр 330
Кадыйров Р.С. 50
Казаковлар 246
Казимбәк А.К. 92, 127, 291, 294, 387, 458
Казимбәк М.К. 138, 383
Казыйханов В.С. 216
Калинин Н. 464
Камал Г. 68, 113, 171, 202, 293, 314, 323, 383, 391, 463
Камал Ш. 98, 109, 113, 116, 293, 336, 452, 464
Камали Закир 189
Камали Зыя 297
Камали С. 247
Камалов А.З. 224, 394, 439
Камалова З.Ф. 225
Кандалый Г. 17, 56, 109, 170, 393
Капустин М.Я. 136

Карамзин Н.М. 313
Каргалый Ә. 113, 371
Кармыш 45
Касыйм хәзрәт 248
Катанов Н.Ф. 14, 16, 21, 22, 39, 43, 46, 48, 51, 56, 57, 74, 81, 82, 85, 86, 110, 121, 124, 126, 136, 151, 202, 226, 228, 297, 339, 348, 359, 379, 383, 387, 412, 429, 457, 464
Кашапов Д. 330
Кашапова Э.Ф. 330
Кашгари Мәхмүд 277, 387
Кашшаф Гази 198
Кәйкавус бине Искәндәр падишаһ 194
Кәлимулла 302, 303
Кәрим Ф. 176, 198
Кәрим хәзрәт 315
Кәрими Ф. 140, 178, 179, 297, 452, 464
Кәримов Мөхәммәтҗан 259
Кәримов Мөхәммәтша 400
Кәримов Х. 259
Кәримов Ш. 259
Кәримовлар 259
Кәримуллин Ә.Г. 20, 24, 102, 259, 272, 334, 375
әл-*Кәчимири* Габдулла бине Таҗетдин 182, 183, 261, 453
Кемпер М. 261
Кербель Л.Е. 53
Киеков Г.М. 437
Клеменц Д.А. 356
Клодт П.К. 52
Ключевский В.О. 313
Ключников В.М. 437
Коблов Я.Д. 266, 311
Ковалевский О.М. 458
Козлов Г.А. 400
Козлянинов П.Ф. 92, 93, 260
Кол Гали 116
Коләхмәтов Г. 77, 121, 269, 464
Колбарисов Ф. 232
Конанбаев Абай 258
Кононов А.Н. 24, 63, 102, 103
Корбангалиев М.Х. 23, 70, 80, 128, 132, 171, 183, 252, 267, 323, 381, 389
Корбанов Т.Я. 24, 269
Коринфский М.П. 272
Королёв Б.Д. 400
Королёв Ю.К. 99
Корсаков Д.А. 46, 263, 340
Котб, татар шагыйре 51
Крачковский И.Ю. 126, 408
Кротов П.И. 46
Куделькин В.И. 99
Кукляшев С. 14, 72
Кулиев И. 122
Кулсар 303
Куприянов В. 212
Курбатов Х.Р. 24, 273
Курсави Г. 55, 97, 109, 113, 147, 170, 217, 226, 291, 379, 381, 454
Кутуй Гадел 464
Кушаевлар 246
Латыйф Г. 252
Лебедев А.А. 126
Лемерсье-Келькеже Шанталь 21, 278
Лепёхин И.И. 458
Лепоринский И. 10, 213
Лермонтов М.Ю. 34, 126
Лиманов И. 179
Лихачёв А.Ф. 42, 383
Лихачёв Н.П. 42, 46
Лия Габдрахман кызы 327
Лобачевский Н.И. 206, 313
Ломоносов М. 149
Лотфи Г.М. 55, 279, 375
Лука Конашевич 31, 200
Мавраев Магомед-Мирза 32
Мавровская М.К. 354
Магницкий Л.Ф. 38
Майоров Б.И. 99
Макаренко А.С. 269
Македонский Александр 241
Максимов К.Е. 281, 354
Максимов Н.В. 283
Максуди Ә.Н. 74, 128, 132, 140, 178, 179, 283, 453
Максуди С. 192, 284
Максудов Г. 131
Маликов В.М. 52
Малов Е. 264, 464
Мамышев Д.Х. 94
Манатов Ш. 166
Маннур Ш. 77
Мансур мулла 45
Мансуров Р.М. 285, 373
Мария Александровна 207
Масловский П.П. 10, 22, 93, 214, 286, 465
Матвеев А.Т. 52
Маһикамал Әхмәтҗан кызы 327
Маһиярова З.М. 287
Машанов М.А. 383
Мәдхи Хәсән 54
Мәймүнә 302, 329, 330
Мәмәткол, Ачасыр авылы мулласы 44, 45
Мәмәтовлар 200
Мәмәш Муса 115
Мәңгәр Ә. 300
Мәрданов Р. 446
Мәржани Ш. 10, 16, 31, 47, 55, 76, 85, 97, 105, 115, 117, 181, 191, 202, 215, 226, 231, 232, 245, 247, 248, 249, 291, 301, 357, 381, 383, 384, 400, 425, 432, 454, 457, 458, 464, 467
Мәсгуд әл-Болгари 51
Мәүлә Колый 116, 170
Мәүлетов Х. 188
Мәхмүдов Ә.Г. 293
Мәхмүдов М. 69, 70, 171, 202, 203, 216, 294, 387, 389
Мәхмүтов М.И. 63
Мәхмүтов Х.Ш. 24, 63, 102, 103, 295, 368, 375
Мәхмүтова Л.Т. 63
Мәхмүтова Ф.Т. 296
Мәһдиев М.С. 24, 296, 387, 389
Мелиоранский М.П. 276

Мидхәт Әхмәт 283
Миндубаев Ә.С. 63
Минкә 303
Минкин К.В. 301, 326, 329, 330
Миннегалиев Х.Х. 286, 355, 373
Минһаҗева Г.Ю. 230, 303
Минһаҗева Л.И. 303
Минһаҗева Н.М. 330
Минһаҗевлар 330
Миңлекәй С.К. 304
Миңнегулов Х.Й. 305
Миңнуллин Җ.С. 233, 307
Миңнуллин Р.М. 156, 308, 448
Миңнуллин Т. 68, 422
Миңнуллина Л.Җ. 260
Мирхазова Н. Р. 309
Мирхәйдәр, Бохара әмире 115
Митонин, Кирмәле авылы алпавыты 44
Михайлов Ф.М. 354
Михайлова С.М. 24, 103, 313, 387
Михалковский Э.К. 95
Мищенко Ф.Г. 136
Мияссарова И.Х. 314
Мозаффар Мөхәммәҗән 315
Мозаффар Мөхәммәткамал 180, 315, 453
Мозаффар Мөхәммәтхәнәфи 168, 181, 293, 315, 357, 453
Мозаффария Mahруй 109
Морад мулла 147, 381
Морат III 54
Мортаза мулла 45
Мортазина Л.Р. 355
Мостафин Р.Ә. 316, 389
Мостафин Х. 286, 373
Мөрсәлим хәзрәт 45
Мөсәгыйть, К.Насыйриның хатынының этисе 247
Мөслими Х. 425
Мөхәммәд бине Касыйм бине Ягъкубның (Зәмәхшәри) 405
Мөхәммәд ибне Әхмәд әл-Хатыйп 405
Мөхәммәд пәйгамбәр 241, 292
Мөхәммәдиш Р.С. 300, 301, 318
Мөхәммәдкәрим бине Мөхәммәдрәхим 226
Мөхәммәдов Ш. 109, 464
Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашыти 429
Мөхәммәдъяр 170
Мөхәммәдъяр мулла 45
Мөхәммәдъяров Ф.Г. 23, 233, 257, 300, 319
Мөхәммәтгалим 9, 325, 326, 328
Мөхәммәтгәрәева Г.В. 320
Мөхәммәтҗан Мифтахетдин угылы 212, 237
Мөхәммәтҗан 181
Мөхәммәтҗанов И.М. 320
Мөхәммәтҗанов Ш. 400
Мөхәммәтнәҗип бине Шәрәфетдин әл-Кустрамави 347, 382
Мөхәммәтнәҗип Галиәкбәр угылы 213, 237
Мөхәммәтов Х. 24, 375
Мөхәммәтов Х.М. 321
Мөхәммәтрәхимов М. 202, 226
Мөхәммәтсадыйк, Мусин Гайса улы 324
Мөхәммәтсафа, мөфти 69
Мөхәррәмов М.К. 24, 102, 170, 322, 387
Мукаев Х. 9, 44, 264, 302, 325, 330, 429
Муллин Б. 246
Мусин Г.Я. 266
Мусин Гайса 247, 324, 344
Мусин М.Г. 216
Мусин Мөхәммәтгали 324
Мусин-Пушкин М.Н. 92
Назмизадә әфәнде 194
Насретдин әл-Хуҗаши 180, 183
Насыйбуллов Р. 446
Насыйрилар 229, 325
Насыйрия Х.Г. 245,326, 327, 330
Насыйров Габделбарый 185, 233, 257, 331, 332
Начиз Габдеррахман 389
Нәҗми К. 198, 464
Нәкъкаш Н. 446, 447
Нәфисә 197, 302, 303, 329, 330
Неплюев И.И. 370
Нефёдов Ф.Д. 42
Нигъмәти Г. 297
Нигъмәтулла улы Мөхәммәтвәли 326
Нигъмәтуллина Р.Р. 406
Нигъмәтуллина Р.Х. 52
Низами Г. 53
Низамиев М.Т. 49
Низамов А.М. 332
Низамов Р.А. 333
Никольский М.Г. 92
Никольский Н.В. 48
Ниязбаев Г. 180, 433
Ногман М.Н. 24, 272, 278, 333
Ногманов Г. 185, 233, 257, 263, 334, 468
Носов В.В. 355
Нури З. 422
Нуриева А.Х. 335
Нуркин З. 75, 132
Нуруллин И.З. 24, 57, 336, 393
Обнорский С.П. 23, 256
Османов Магомед-Нури 34
Охотин В.А. 136
Өҗем баба 44
Өметбаев М. 389
Павлов Л.Н. 53
Паллас П.С. 458
Парсин М.З. 23, 132, 343
Паульсон И.И. 38
Перич М. 70
Перов И.С. 344
Пётр I 42
Пинегин М.Н. 216
Писарев, студент 256
Писаревский Л.М. 53

Платон, грек философы 42
Поляков П.А. 15, 48, 57, 81, 101, 297, 311, 348, 399, 411, 412, 458
Пономарёв П.А. 42, 46
Попов В. 446
Потанин Г.Н. 46
Пугачёв Е.И. 31
Пушкин А.С. 34, 41, 126
Радлов В.В. 10, 14, 16, 22, 35, 43, 46, 69, 85, 124, 126, 179, 182, 202, 203, 214, 215, 291, 293, 294, 297, 356, 359, 361, 362, 363, 379, 390, 412, 434, 457
Рамазанов Ш.Г. 12, 23, 24, 232, 257, 357, 387, 464
Рамазанова Д.Б. 278
Расих А. 422
Рафикъ Бәдигъ улы 94
Рахманколый Габделмәннан 202
Рахманкулов М. 400
Рахманкулов Х. 294
Рәмиев З. (Дәрдемәнд) 109, 113, 176, 384, 400, 407, 452
Рәмиев И. 464
Рәмиев Мөхәммәтшакир 407, 452
Рәмиев С. 67, 109, 113, 116, 122, 391, 464
Рәмиевләр 452
Рәсүлев Зәйнулла 75
Рәхим Г.М. 23, 42, 43, 132, 174, 248, 252, 297, 353, 358, 410, 412, 464
Рәхимов М. 354
Рәхимова Р.К. 25, 162, 360, 369
Рәхмәт мулла 46
Рәхмәтуллин Ә. 226
Рәхмәтуллин Ю.С. 265
Рена, француз галиме 79
Роден Огюст 52
Руми Җ. 464
Рыбушкин М.С. 458
Рысбуга (Рысбай) 44
Рюрик 207
Саблуков Г.С. 10, 22, 85, 124, 202, 214, 297, 364, 379
Садриев Ә.Ш. 365
Садыйкова С. 448
Сайманова Х.Г. 463, 465
Салахов И. 304
Салиәхмәт К. 300
Салих 255
Салихов Касыйм, мулла 248
Салихов М. 14
Салихов Мөхәммәткасыйм 226
Салихов Мөхәммәтшакир 339
Салихов Һ. 371
Салихов Ш. 203, 344, 362
Самойлович А.Н. 80, 408
Сараи Сәйф 51
Саттаров М.Г. 330, 384
Сафиуллина Ф.С. 278, 369
Сая Ибрай 344, 361
Сәгъди Г.Г. 10, 70, 128, 297, 371, 375, 389
Сәгъди, Ачасыр авылы мулласы 44
Сәгъдуллина Г.Н. 321
Сәгыйдә Зәйнәп 109
Сәгыйтов Әхмәт 115
Сәгыйтов Габдессаттар 115
Сәгыйтов Исхак 226
Сәгыйтов Мөхәммәтйосыф 94, 115, 202, 248
Сәгыйтов Сәлахетдин 226
Сәгыйтовлар 329, 447
Сәгыйть 453, 454
Сәгыйть бине Әхмәт 115
Сәет Яхъя Зыятдин 54
Сәет 45
Сәйфетдин Сөбханкол улы 93
Сәйфи-Казанлы Фатих 70, 132, 166, 297
Сәләм мулла 264
Сәмитова Газизә 109
Сәнаи Хәким 464
Сәхибгәрәй хан 383
Сбоев В.С. 458
Семёнов М.А. 344
Симонов Н.И. 313
Смирнов В.Д. 21, 22, 56, 85, 373
Смирнов И.Н. 46, 48
Сократ 241
Соловьёв А.Т. 48, 136
Соловьёв С.М. 313
Солтан Әмәтхан 53
Солтангалиев Я. 247
Солтанова Р.Р. 459
Сосунцов Е.Ф. 136
Сөбханколов С. 94
Сөендековлар 283
Сөләев Х. 300
Спицын А.А. 46
Субур Хәйрулласы, бай 265
Сутюшев М. 400
Сүнчәләй С. 77, 391, 464
Сүнчәләй Ш. 166
Такташ Һ. 77, 417, 464
Таһир бине Сөбхан әл-Адайи 379, 454
Таһир мулла 44, 50
Таһири Һади 179, 385, 453
Таһиров И. 87
Таһиров Ш.Ә. 215
Тәфкилев С. 231
Терегулов Г.Х. 467
Терегулов Гомәр 75
Терегулов И.В. 35, 69, 179, 215, 362, 390, 215
Тимергали мулла 45
Тимофеев, нәкышьче 400
Тинчурин К. 68, 77, 464
Тихов Н.З. 48
Толстой Л.Н. 126, 273
Томсен Вильгельм 457
Томсон Уильям 410
Төхфәтуллин Г. 185, 233, 257, 390, 468
Траубенберг П.В. 48, 215
Троянский А.А. 70, 213, 387
Трубецкой П.П. 52
Тукай Г. 33, 40, 57, 67, 73, 83, 97, 109, 113, 116, 122, 171, 248, 279, 293, 314,

323, 336, 337, 382, 383, 384, 391, 400, 405, 412, 417, 463
Тукмаш мулла 44
Туктамышев Н.К. 224, 394, 439
Туктаров Фоат 75, 121, 180, 433, 467
Туфан Х. 108
Тунтәри М. 168, 181, 395, 453
Тюзел И. 313
Укмасый М. 184, 375, 396
Уразаев И. 115
Уразаева Ш. 325
Уразай 303
Уразиков Х. 113, 231, 232
Уразманова Р.К. 24, 103, 399, 459
Урманче Б.И. 354, 399
Усманов Ж. 247
Усманов Ш. 469
Устрялов Н.Г. 241, 313
Утыз Имәни Габдерәхим 17, 56, 109, 113, 116, 170, 217, 371, 379, 381
Ушинский К.Д. 18, 73, 89, 269, 273, 418
Фазлуллин М.Ә. 23, 257
Факиһә 328, 329
Фасиев К.Ф. 24, 63, 102, 403
Фасиев Ф.С. 24, 102, 103, 128, 387, 404
Фәезханов Г. 14, 339, 389
Фәезханов Хөсәен 10, 55, 245, 301, 381, 387, 389, 432, 457
Фәзлулла 303
Фәйзерахман хәзрәт 179, 192
Фәйзи Мирхәйдәр 68
Фәйзи-Чистапули Х. 120
Фәизов 205
Фәизова Ф.С. 406
Фәйзуллин Р. 156
Фәтхи А. 24
Фәтхуллова К.С. 406
Фәхретдин Ризаэтдин 22, 31, 57, 76, 85, 140, 153, 178, 179, 191, 297, 384, 407, 425, 452, 453, 466
Фәхретдинов Р.Г. 24, 103, 276, 380, 381, 409, 457
Фирдәүси 431
Фирсов Н.А. 16, 47, 85, 121, 379
Флюгель Густав 138
Фомин А.А. 29
Фортунатов Я.И. 255
Фөзули 431
Френ Х.Д. 364
Фукс А.А. 458
Фукс К.Ф. 458
Хаҗ Гали 43
Хаҗи ахун 371
Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булат 277
Хаков В.Х. 24, 63, 103, 128, 331, 387, 389, 414
Халиков А.Х. 415
Халиков Ф.Г. 354, 415
Халит Г.М. 25, 375, 387, 417, 464
Халитов Ф. 232
Ханбиков Я.И. 24, 375, 417
Ханбикова Ш.С. 24, 25, 63, 103, 278, 418
Хангилдин В.Н. 23, 25, 128, 232, 257, 277, 278, 375, 387, 388, 419
Харисов Ф.Ф. 420, 421
Харисова Ч.М. 420, 421
Харлампович К.В. 48, 287
Хәбибуллина З.Н. 421
Хәбибуллина Л.Б. 422
Хәбирә 165
Хәдичә 302, 303
Хәйдәрова Р.З. 423
Хәйретдинов А.Г. 424
Хәйри Ә.Н. 24, 63, 103, 235, 300, 389, 424, 425
Хәйруллина Н. 376
Хәким Н. 128
Хәкимов К. 188
Хәкимов Х.Х. 103
Хәкимова Р.А. 23, 233, 257, 387, 426
Хәлим, мәдрәсә шәкерте 190
Хәлимова К.Б. 427
Хәлфин И.И. 127, 387
Хәлфин Ибраһим 432
Хәлфин Н. 121
Хәлфин С.Х. 127, 387, 432
Хәмзин Ә. 275
Хәмид карт 264
Хәмидуллина М.З. 427
Хәсән (Чуаш иле Хәсән) 247
Хәсәни Ә. 297
Хәсәнов М. 448
Хәсәнова Н. 303
Хәялин С. 370
Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Болгари (Хисаметдин Мөслими) 243, 425
Ходайберды (Ходайбирде) 303
Ходайбирдин Ш. 188
Хөсәенов Әхмәт Мөхәммәтбәдигъ улы 119, 183, 184, 328, 375, 430, 431
Хөсәенов Габденнасыйр 9, 37, 157, 229, 264, 325, 327, 328, 329, 330, 378, 401, 429, 431
Хөсәенов Габдрахман Габделкави улы 179, 266, 327
Хөсәенов И.С. 328
Хөсәенов Мөхәммәтбәдигъ Мөхәммәтгалим улы (Бәдигъ мөәзин) 22, 93, 94, 182, 183, 244, 247, 248, 249, 261, 324, 329, 344, 391, 430, 432
Хөсәенов Мөхәммәтгалим 431
Хөсәенов Р. 432
Хөсәенова Р.Ф. 327
Хөсәенова Фатыйма 229, 325, 329
Хөсәенова Х.Г. 327, 328
Хөсәеновлар 245, 371
Хөсәенов-Насыйровлар 328, 330

Хөснетдин 9, 302, 325, 329, 330
Хөснетдинов Р.Р. 24, 355
Хөснетдинова Р.С. 245, 375, 432
Хөсни мулла 264
Хөснижамал абыстай 186, 332
әл-*Хуҗаши* Насретдин 168, 433, 453
Хуҗиәхмәтов Ә.Н. 24, 434
Һади Закир 109
Һибәтулла мулла 45, 264
Царёв С.В. 354, 436
әл-Чәгъмини 220
Чәләби Мөхәммәд 44, 217, 288, 379
Чижова Н.М. 437
Чокрый Гали 181
әл-*Чокрый* Гарифулла бине Гали 168, 181, 437, 453
Чокрыкчызадә 288
Чутай Мостафа 425
Чыршы Габди 248, 344
Шайдаева (Зәйнетдинова) Л.Н. 107, 405, 438
Шакиржанов Р.Ә. 224, 235, 394, 438
Шамов А. 149
Шаһи Я. 247, 357
Шаһморатовлар 200
Шаһсуаров Б. 78
Шәгъбан бине Әсәд 44
Шәехби 44
Шәйдуллин Р.В. 443
Шәймәрданов Р.Х. 24, 355
Шәймәрданов Ш.Ш. 23, 67, 132, 444
Шәйхелисламов З.Р. 25, 299, 445
Шәкүрова М.М. 24, 355
Шәмгун мулла 45
Шәмсетдинов И.Н. 94, 126, 140, 146, 172, 173, 275, 348
Шәмсетдинов Р.Г. 329, 330, 447, 448
Шәмсетдинов Х. 175
Шәмсетдинова Р.Р. 376, 449
Шәмсуаров Ш. 465
Шәмсутов Р. 446
Шәрәф Б. 121
Шәрәф Г. 80, 121, 268
Шәрәф Р. 384
Шәрәфетдинов В.Ш. 266, 354, 450
Шәрәфетдинова Р.М. 103, 300
Шәрәфиев Ф. 232
Шәрифуллина Ч. 446
Шәрифуллина Э.М. 230, 450
Шәфигуллина Р.Ф. 379, 424, 451
Шевченко А.В. 400
Шервуд Л.В. 52
Шестаков П.Д. 47
Шикалов Н.С. 400
Ширази С. 464
Шихалиев Дәүләт-Мирза 34
Шишкин И.И. 281
Шпилевский С.М. 42, 47
Штернберг Л. 215
Штукенберг А.А. 42, 47
Шубин Ф.П. 52
әш-*Шырдани* Әхмәт бине Сәгыйть 202, 226, 453
әш-Шырдани Сәгыйть бине Әхмәт 115, 371, 329, 379, 447
Щапов А.П. 313
Энчек 44
Юзеев И. 156, 422
Юзиев Н. 74
Юнысов И. 226, 231, 232
Юнысовлар 200, 247
Юсупова Э.Ш. 24, 277, 278, 387
Ягъфәрова Р.Х. 462
Якупов Х.Г. 415
Ямалтдинова С.Т. 466
Ямашев Х. 384
Ямбушев Ф.Ж. 466
Янчек 44
Ярми Х.Х. 14, 23, 25, 110, 141, 165, 185, 232, 257, 264, 334, 390, 467
Яруллина Л.И. 355
Ясәви Ә. 220
Яушев Г. 178, 409
Яхин А.Г. 235, 468
Яхин М. 92, 93, 260
Яхин Р. 448
Яхин С. 203, 344, 361
Яхин Т.Г. 14, 215
Яхин Ф. 74

РӘХМӘТ СҮЗЕ

ТР Фәннәр академиясе Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты «Каюм Насыйри: иллюстрацияле персональ энциклопедия»сен әзерләүгә ярдәм күрсәткәннәре өчен ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе М.Г.Әхмәтовка, ТР Фәннәр академиясе президенты Р.Н.Миңнехановка, ТР Мәгариф һәм фән министры И.Г.Һадиуллинга һәм министрлык хезмәткәрләренә, Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы М.П.Афанасьевка, ТР Милли музее (генераль директоры А.Л.Вяткина, урынбасары С.Ю.Измайлова), Казандагы Каюм Насыйри музее (мөдире К.Б.Хәлимова), Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылындагы Каюм Насыйри исемендәге Архитектура һәм этнография музее (мөдире Р.Ә.Гатиятуллина), Кече Шырдан авылындагы Каюм Насыйри исемендәге музей-китапханә (мөдире Г.Ю.Минһаҗева), Галиәсгар Камал исемендәге Татар академия театры музее (мөдире Л.Г.Шакиржанова), Азнакай туган якны өйрәнү музее (директоры А.Н.Абдуллина), Казан шәһәре музей комплексына караган Бакый Урманче музее (директоры Г.Р.Әсфәндиярова), Казан федераль университеты Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге (мөдире Э.Н.Сабирова), ТР Милли китапханәсе (директоры М.Ф.Тимержанова, фән буенча урынбасары И.Г.Һадиев, татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегенең сектор мөдире Ф.Х.Вәлиева, татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге өлкән библиографы С.И.Миңнеханова), Россия Фәннәр академиясе «Казан гыйльми үзәге» федераль-тикшеренү үзәгенең Үзәк гыйльми китапханәсе (мөдире М.Ә.Әхмәтова), ТР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге (җитәкчесе И.Г.Гомәров), Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Каюм Насыйри институты (директоры Ә.Ш.Юсупова), «Бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган җире — тарихи авыл Кече Шырданны торгызу» фонды (башкарма директоры А.Н.Гобәйдуллина) хезмәткәрләренә, Казан шәһәр думасы депутаты К.З.Хәмидуллинага, Каюм Насыйриның туганнарына (И.Г.Бариев, Н.М.Игъламова, Р.И.Кавиев, К.В.Минкин, Р.Г.Шәмсетдинов һ.б.), төбәк тарихын өйрәнүчеләргә (И.Ә.Кыямов, Г.М.Җәләлов, Р.Ногманов) зур рәхмәтен белдерә.

Э.М.Галимова,
Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры,
сәнгать фәннәре кандидаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе,
РФнең һәм ТРның Композиторлар берлеге әгъзасы,
РФнең һәм ТРның Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы,
М.Җәлил исемендәге Республика бүләге лауреаты

Научное издание

КАЮМ НАСЫРИ
иллюстрированная персональная энциклопедия

Казань. Институт Татарской энциклопедии и регионоведения
имени М. Хасанова АН РТ. 2025

Фәнни басма

КАЮМ НАСЫЙРИ
иллюстрацияле персональ энциклопедия

Казан. ТР Фәннәр академиясенең М.Хәсәнов исемендәге
Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты. 2025

Әдәби мөхәррирләр:
Ф.Р.Бәдретдинова, Г.И.Каюмова
Дизайн һәм тышлык бизәлеше:
Ф.Э.Ибраһимова
Иллюстрацияләрне басмага әзерләү:
Г.Р.Дәүләтьянова, Р.Н.Шакиров
Компьютерда биткә салу:
Р.Р.Сәләхиев, А.Б.Насибуллина

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.02.2025.
Форматы 70×100/16. «Petersburg» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 40,63. Тираж 1000 данә. Заказ 14.2/25

ТР ФАнең М.Хәсәнов исемендәге
Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты.
420015, Казан ш., Пушкин ур., 56.
E-mail: info-ite@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты.
420111, Казан ш., Бауман ур., 20.
E-mail: izdat.anrt@yandex.ru